Рафаил Хәким

# Татар рухы

*Сайланма әсәрләр*

КАЗАН ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ 2007

УДК 94(47):323
ББК 63.3:66.3 (2Рос=Тат)
Х86

**Хәкимов Р.С.**

Татар рухы: сайланма әсәрләр (1989 — 2006) / Рафаил Хәким.— Казан: Татар.кит.нәшр., 2007.— 392 б.— 2000 д.— ISBN 978-5-298-01496-0.

Китапка соңгы 17 елда дөнья күргән сәясәт, милләтара мөнәсәбәтләр, тарих, ислам дине һәм федерализм мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр, мәкаләләр һәм публицистик язмалар туплап бирелде.

ISBN 978-5-298-01496-0

© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Хәкимов Р.С., 2007

ЭЧТӘЛЕК

Халыкмы без, әллә «яшәүчеләр»ме? *...4*
I. Татар милләтенең суверенитеты һәм аны гамәлгә ашыру (*4).* 2. Кешелек һәм милли идея (*10)*
Мөстәкыйльлек әлифбасы *...17*
Татарстанга — союздаш республика статусы! (*17)*
Милли азатлык һәм демократия *...22*
Бәйсезлек сакчысы — халык *...26*
Мөстәкыйль Татарстан: алда безне ни көтә? (*26)*
Империянең кояшы батканда *...29*
КЕРЕШ СҮЗ (*29)*
I БАШЛАМ. Этнос — халык — милләт: дәүләтчелеккә бару (*32)*
I. Милләтара мөнәсәбәтләрнең чиеләнгән төене (*32).* II. Этнос һәм милләт (*36).* III. Этнос берлеге булсын өчен кайвакыт үзаң булу да җитә (*37).* IV. Милли азчылыклар, төп халыклар һәм мигрантлар (*39)*
II БАШЛАМ. Милли азатлык һәм демократия (*43)*
I. Милләтнең азатлыкка таба хәрәкәте буларак демократия (*43).* II. Кеше хокуклары контекстында милли хокуклар (*46).* III. Курку, нәфрәт һәм демократия (*49)*
III БАШЛАМ. Русиянең күрәчәге: җавапсыз сораулар (*53)*
I. Русиянең баганаларын кем какшаткан соң? (*53).* II. Русиянең чик буйлары кайдан үтә? (*56).* III. Федерацияме, конфедерацияме, әллә бәйсез дәүләтләрме? (*58)*
IV БАШЛАМ. Халыкларның үзбилгеләнүе һәм территориаль бөтенлек: халыкара хокук коллизияләре (*62)*
I. Татарстан һәм дөньядагы бүгенге тәртип (*62).* II. АКХКның «җимерелмәс ун сүрәсе» һәм Аурупаның бүгенге көне (*65).* III. Яңа халыкара мөнәсәбәтләргә таба хәрәкәт (*67)*
ЙОМГАК (*71)*
Татарстан кая чыга? *...72*
Кайсы мөһимрәк — халыкның яшәвеме, әллә дәүләтнең бөтенлегеме? (*72)*
Суверенитет кемгә комачаулый? *...75*
Кулдан ычкындырылган мөмкинлекләр елы *...78*
I. Язгы «нарциссизм» (*78).* II. Хокукый дәүләткә — тайгак юлдан(*81).* III. Автономияме яки суверенитетмы?(*85).* IV. Тантана «сәясәте» (*89).* V. Компас «акылдан язса», нәрсә эшләргә кирәк? (*92)*
Русия һәм Татарстан: тарихи юллар чатында *...95*
I. Чечен кризисы «җимешләре» (*95).* II. «Гаага инициативасы» (*99).* III. «Татарстан моделе» — яңа үрнәк (*102)*
Хокукка хак *...107*
Кем син, татар? *...109*
I. Бердәмлек (*109).* II. Тарих (*114).* III. Ана теле (*120).* IV. Культура (*127).* V. «Зур Татарстан» (*132)*
Кайда безнең кыйбла? *...139*
Татар рухы *...186*
«Каһәрләнгән» сораулар (*186).* «Рәхимсезлек» (*197).* Тарих мәгънәсе (*206).* Этноним язмышы (*223).* Тел (*232).* Дала цивилизациясе (*240).* «Мәңгелек Күк Тәңре» (*253).* Хәрби сәнгать (*259).* Ислам (*270).* Сөйкемле «Мәңгелек Төрки ил» (*288).* «Изү» (*318).* Каян килеп чыккан Урыс җире һәм нинди Урыс җире барлыкка килгән? (*324).* Бөек борылыш (*345).* Тарихны җинеп чыгу (*365).* «Татар Русе» (*381).* Йомгак (*388)*
Кушымта *...390*

## ХАЛЫКМЫ БЕЗ, ӘЛЛӘ «ЯШӘҮЧЕЛӘР»МЕ?

*Татары, основное население Тат. АССР...*
*Живут также во мн. др. р-нах СССР.*

Большая Советская Энциклопедия, Москва, 1976

### I. Татар милләтенең суверенитеты һәм аны гамәлгә ашыру

Милләтләрнең Ленин тәкъдим иткән үзбилгеләнү принцибы милләт суверенитетын дәүләт суверенитетыннан да, шулай ук дәүләт чикләреннән һәм идарә итү формаларыннан да өстен куя. Бу — дөньяда гомумтанылган принцип һәм ул бик күп халыкара документларда теркәлгән. Шул исәптән 1966 елда СССР хөкүмәте кул куйган Экономик, социаль һәм мәдәни хокукларның халыкара пактындагы 1 нче статьяда болай диелә: «Барлык халыклар да үзбилгеләнү хокукынура ия. Шушы хокук нигезендә алар ирекле рәвештә үз политик статусларын билгелиләр һәм үзләренең экономик, социаль һәм мәдәни үсешләрен ирекле рәвештә тәэмин итәләр». Татар милләтенә карата бу принцип ни дәрәҗәдә гамәлгә ашырыла соң?

Билгеле бер этнос буларак, татар халкы федератив система ярдәмендә түгел, ә киресенчә, шушы система булуга да карамастан һаман яшәп килә. Бүгенге көндә СССР хөкүмәте югарылыгында да, РСФСР хакимияте даирәләрендә дә бөтен бер милләтне тәшкил иткән татар халкының яшәү факты белән күпмедер дәрәҗәдә хисаплашучы бер генә дәүләт механизмы да юк. Татарстан Республикасы ул — бары тик шушы территориядәге халыкның гражданлыгын чагылдыручы форма гына.

Үз составына автономияләрне алган Русия Федерациясен төзү идеясе Сталин тарафыннан ныклап уйланылган. Әле 1913 елда ук ул хәтта Польша, Литва, Украина һәм Кавказ кебек регионнарга да бары тик автономия статусын бирүне генә күздә тота. Русия Федерациясе инде төзелеп яткан заманда — 1920 елда язган мәкаләләрендә дә ул шушы идеяне алга сөрә. «Яшәү рәвеше һәм милли составы белән аерылып торган төбәкләрне федерация багланышлары белән үзәккә бәйләп куярга тиешле бердәнбер кулай форма булып автономия — өлкәләр автономиясе кала»,— дип яза Сталин (Сталин И.В., 4 т., 354 б.). Шул уңайдан Сталин дүрт рангтагы автономияләр булдырырга тәкъдим итә: 1) тар, административ автономия (немецлар, чувашлар, кареллар); 2) политик автономия (башкортлар, татарлар, кыргызлар); 3) киңәйтелгән политик автономия (Украина, Төркестан); 4) договор нигезендә төзелгән автономия (Азәрбайҗан). Бу планны тәүге формасында тормышка ашыруга «Грузия инциденты» комачаулый. Грузия коммунистлары, алар артыннан Украина коммунистлары да Русия Федерациясенә автономияле республика хокуклары белән керүдән баш тарталар. Бу инцидент Ленинны бик нык борчуга сала, ул моны партиянең эчке конфликты дип кенә карамый, аңарда федерация төзүдә ясалган җитди хата күрә. «Күрәсең, бу «автономияләштерү» белән мавыгу тамырдан дөрес түгел һәм вакытсыз да, ахры»,— ди Ленин ВКП(б)ның XII съездына язган хатында, шунда ук Сталинны ашыгуда һәм соңрак үтә дә аяныч хәлләргә китергән администраторлык белән мавыгуда гаепли (Ленин В.И., 45 т., 356 б.).

СССР төзелү уңаеннан көн тәртибенә РСФСРны тарату мәсьәләсе килеп баса, автономияле республикаларның да СССР составына, башка республикалар кебек, тулы хокуклы булып керүе күздә тотыла. Ләкин Сталин үз баласы булган РСФСРны яклап кала. «Минем уемча,— дип сөйли ул Бөтенрусия Советларының X съездында,— бу рациональ юл түгел, өстәвенә максатка да туры килми һәм кампаниянең барышы белән кире кагыла. Беренчедән, ул республикаларның берләшү процессында туып өлгергән федераль оешмаларның аерылуына китерер иде, бу исә республикаларның революцион берләшү процессын тулысынча юкка чыгара. Икенчедән, әгәр дә без шушы ялгыш юлдан китсәк, хәлләр шундый борылыш алыр иде ки, ул чакта сигез республикага өстәп, РСФСРдан махсус урыс ВЦИКы һәм урыс Совнаркомы бүлеп чыгарырга туры килер, бу исә үз чиратында оештыру эшләренә хәзерге моментта бөтенләй кирәксез һәм зарарлы зур буталчыклар кертер иде. Эчке һәм тышкы хәлләрне искә алсаң, бу хәзерге вакытта һич тә акланмый. Менә ни өчен мин союзга берләшергә тиешле субъектлар дип дүрт республиканы атыйм: РСФСР, Кавказ арты федерациясе, Украина һәм Белоруссия» (Сталин И.В., 5 т., 151—152 б.).

Сталин алдаша, әлбәттә. РСФСРда ул чакта ук инде урыс ВЦИКы һәм Совнаркомы функцияләрен башкаручы югары органнар булган. Хикмәт анда түгел. Сталинга ничек тә рангларга бүленгән «автономияләр» идеясен яклап калырга кирәк булган. РСФСР сакланып калган очракта, татарларга да дәүләт ише бернәрсә бирелгән булып чыга, ә милли үзенчәлекләреннән мәхрүм ителгән урыслар исә дәүләтчелек идеясе белән тиңләшәләр, дөресрәге, дәүләт бюрократиясен гәүдәләндерәләр.

Ләкин ул чакта бит инде милләтләрнең үзбилгеләнү принцибы бар, һәм, гәрчә авыру сәбәпле СССРны төзүдә катнаша алмаса да, Ленин үзе дә әле исән, Сталин бу принципны капма-каршысына үзгәртә. 1913 елда ул аны болай аңлаткан иде: «Үзбилгеләнү хокукы — ягъни милләт үз язмышын фәкать үзе хәл итә,

беркем дә милләт тормышына көчләү юлы белән катнаша алмый, аның мәктәпләрен һәм башка оешмаларын җимерә, гореф-гадәтләрен бетерә, телен кысрыклый, хокукларын чикли алмый» (Сталин И.В., 2 т., 310 б.). Ул чакта Сталин әле демократ иде. 1920 елны бу принцип инде «автономияләштерү» политикасын үткәрергә комачаулый, һәм Сталин аны төзәтә: «...Халык массалары интереслары революциянең хәзерге дәверендә окраиналарның аерылып чыгуны таләп итүен үтә контрреволюцион эш дип таба»,— ди (Сталин И.В., 4 т., 354 б.). 1922 елны аерылып чыгу хокукына булган мөнәсәбәтен ул тагын да кискен төстә: «Үзбилгеләнү хокукы эшче сыйныфының үз диктатурасын үткәрүе өчен киртә булмаска тиеш һәм була да алмый. Беренчесе икенчесе алдында чигенергә тиеш»,— дип белдерә (Сталин И.В., 5 т., 265 б.). Шулай итеп, дәүләт суверенитетының милләт суверенитетыннан өстен булуы «законлаштырыла» да куела. Моннан соң инде пролетариат диктатурасы хакына халыкларны ни эшләтсәң дә була.

Татар милләтенә каршы юнәлтелгән беренче һөҗүм автономияле ике республика төзү юлы белән безнең халыкны икегә бүлүдән башланды. Шушы бүлгәләү аркасында башкортлар үз республикаларында азчылыкта калдылар. Татар халкын бүлгәләү, аннан соңгы тормышын Татарстан рамкалары белән чикләп кую Сталинга татарлар өстеннән шактый җиңел идарә итү мөмкинлеген бирде, җитмәсә, Татарстан һәм Башкортстан арасында даими көндәшлек атмосферасы тудырды. Башкортстанның үзендә исә сан ягыннан ишлерәк булган татарлардан шикләнү тәрбияләнеп килде. Башкортстандагы булган хәлләр шушы политиканың нәтиҗәсе булып тора.

Татарларны милләт буларак какшату юнәлешендәге икенче адым милли уку йортларын ябу, матбугатны, нәшриятларны, мәдәни оешмаларны бетерүдән гыйбарәт иде. Әгәр дә 20 нче елларда әле татарларның бөтен ил буенча таралып яшәве мәктәпләр, училищелар, институтлар, клублар, театрлар челтәренең эше, йөзләгән газета-журналлар чыгу, татар-башкорт эшләре буенча рәсми институтлар структурасы булу аркасында милли ихтыяҗларны канәгатьләндерүдә әллә ни кыенлыклар кичермәсә, 30 нчы еллар уртасында инде татарларның мәдәни тормышы ТАССР рамкалары белән торган саен чикләнә барды, ә ТАССРның үзендә рухи культураның үсүе өчен шартлар һаман кимеде. Нәтиҗәдә Урта Азия белән Казахстанда яшәүче 1 миллионнан артык татарларның милли мәктәбе дә, клублары, газеталары да юк. Себердә, Уралда, Украинада яшәүче милләттәшләребезнең дә хәле әйбәт түгел. Шулай ук гомер бакый Башкортстанда яшәгән татарларның мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү дә четерекле мәсьәләгә әверелде, чөнки аларның социаль һәм мәдәни тормышта катнашуын тәэмин итүче бернинди механизм юк. ТАССРдан читтә гомер итүче милләттәшләребезне республика белән бәйләүче рәсми каналлар да шул ук хәлдә. Шушы сәбәпләр аркасында татар милләтенең тормышы аерым-аерым утрауларга таркалды, атомлашты, һәм бу хәл социаль һәм милләтара киеренкелекне китереп чыгарды.

Татарстанда хәзер халкыбызның 25 проценты гына яши, урыс телендә сөйләшүче халыкның даими күчеп килүе сәбәпле, татарларның өлеше кимегәннән-кими бара, һәм 90 нчы елларда инде безнең халыкка үз республикасында азчылыкны тәшкил итү куркынычы яный.

Халкыбызның милли тормышын бары тик Сталин тудырган политик системаны һәм дәүләт төзелешен тулысынча сүтү юлы белән генә кабат нормаль хәлгә кайтару мөмкин.

Сталиннан калган политик мирас бүгенге көндә шуннан гыйбарәт: 1) татар халкының тормышын Татарстан рамкалары белән чикләү дәвам итә. Татарлар күп яшәгән РСФСР өлкәләре бермилләтле территория дип карала. Шул ук хәл Урта Азиядә, Казахстанда, Украинада да саклана; 2) ТАССР органнары белән татарлар ишле урнашкан республикалар, өлкәләр органнары арасында дәүләт мөнәсәбәтләрен урнаштыручы рәсми структуралар әлегәчә юк; 3) ТАССРның бюджеты республикада яшәүчеләрнең ихтыяҗын канәгатьләндерүне генә күздә тота һәм СССРдагы 7 миллион татар халкының дәреслекләргә, уку әсбапларына, матур әдәбиятка, сәнгатькә булган ихтыяҗларын берничек тә исәпкә алмый; 4) автономияле республика статусы татар милләте үсешен һәм шулай ук республикада яшәүче халыклар үсешен тоткарлаучы төп факторга әверелде; 5) Татарстан практик яктан берничек тә РСФСР һәм СССР политикасына тәэсир итә алмый, ул илдә яшәүче татар халкы интересларын яклау мөмкинлекләреннән мәхрүм ителгән.

Ленин үзе Татарстан Республикасы төзелү турындагы декретка кул куйса да, 1922 елны язган соңгы хатларында зур үкенү белән болай ди: «Минем Русия эшчеләре алдында зур гаебем бар сыман, чөнки ямьнаты чыккан автономияләштерү мәсьәләсендә тиешенчә нык һәм тиешенчә кискен итеп сүземне әйтә алмадым, рәсми телдә ул социалистик республикалар союзы мәсьәләсе дип йөртелә шикелле» (Ленин В.И., 45 т., 356 б.).

Автономияле республика, аның Конституциясен никадәр камилләштермәсеннәр, барыбер татар халкы үсеше тудырган ихтыяҗларга җавап бирә алмаячак. Алай гынамы соң, автономия принцибы, гомумән, халкыбыз суверенитеты белән каршылыкка килә. Ил һәм республика Конституциясе буенча ТАССР суверенитетка бөтенләй ия түгел. Аның суверенитеты тулысынча РСФСР карамагына тапшырылган. Ә РСФСРның үзендә исә татар халкы мәнфәгатьләрен кайгыртучы органнар бөтенләй юк (шулай ук башка халыкларны-

кын да), ягъни ТАССР татар милләтенең үзбилгеләнү формасы буларак каралмый һәм аның РСФСРдагы хәле гади бер өлкә статусыннан берничек тә аерылмый. Мондый хәлнең урнашуына һәм дә шул көенчә яшәп килүенә «милләтара мөнәсәбәтләр» дигән төшенчәнең теоретик яктан эшләнмәгән булуы сәбәпче, чөнки ул еш кына яки артык абстракт формада, ягъни милләтләрнең бер-берсенә карата хокукларын һәм бурычларын ачыклап тормастан, дустанә мөнәсәбәттә яшәве дип аңлатыла яисә, чамадан тыш конкрет кабул ителеп, аерым милләт вәкилләренең үзара мөнәсәбәтенә кайтарып калдырыла.

Милләтара мөнәсәбәтләр — мөстәкыйль (суверен) хокуклы, үзбилгеләнү ягыннан язмышларын үзләре билгеләүче, ут күршеләренә булган мөнәсәбәтләрдә, уртак идарә формалары сайлаганда барысын да фәкать үзләре хәл итүче халыклар арасындагы мөнәсәбәтләр ул.

Мөнәсәбәтләр урнашканчы ул мөнәсәбәтләрне урнаштыручы субъектлар булырга тиеш. Урыс белән татар арасындагы мөнәсәбәтләргә килгәндә, бу очракта андый субъектлар сыйфатында, бер яктан, Русиянең югары органнары, икенче яктан, Татарстан югары органнары торырга тиеш. Хәзерге көндә татар милләте мәнфәгатьләрен кайгыртучы бердәнбер орган булып ТАССР Югары Советы тора. Бүтән бер генә республика яки өлкәдә дә халкыбыз ихтыяҗларын кайгыртучы рәсми структура юк. Кызганычка каршы, ТАССР да үзенең шушы бурычын кәгазьдә генә башкара. Өстәвенә мәсьәлә шулай куелган ки, ТАССР республиканың үзендә яшәүче кешеләрнең мәнфәгатьләрен кайгыртучы форма сыйфатында гына кабул ителә.

Татарстанның үз суверенитетын РСФСР органнарына тапшыруына өстәп аның шушы органнар чыгара торган карашларга тәэсир итә алмавын да әйтергә кирәк, чөнки РСФСРда федерация члennары вәкил булып торырлык Милләтләр Советы юк. Бу инде федерация үзе юк дигән сүз, икенче төрле итеп әйтсәк, федерация урынына бөтен вәкаләтләрне бер йодрыкка туплаган, үзәктән идарә итүче дәүләт яши. Шуңа күрә Русия составына кергән халыклар язмышына кагылган барлык мәсьәләләр РСФСР органнарында гади тавыш бирү юлы белән хәл ителә, ә тавыш бирүчеләрнең абсолют күпчелеге урыс милләтеннән. Милләтара мөнәсәбәтләр, гомумән, тавыш бирү юлы белән хәл ителә алмыйлар, чөнки андый мөнәсәбәтләр үзара килешү, договор нигезендә хәл ителергә тиешләр. Демократик күпчелек белән хәл ителә торган мәсьәлә түгел бу.

Йөзләрчә мең татар яшәгән Урта Азиядә исә милләтара мөнәсәбәтләр тагын да катлаулырак. Әйтик, үзбәк белән татар, казах белән татар арасындагы мөнәсәбәтләр дәүләт югарылыгында Үзбәкстан ССР һәм ТАССР, Казахстан ССР һәм ТАССР мөнәсәбәтләредәй булырга тиеш иде. Әмма андый мөнәсәбәтләр урнаштырырга Татарстанның хокукы юк, чөнки суверенитеты РСФСРга тапшырылган, ә суверенитетыбыз тапшырылган РСФСРда исә татар халкы мәнфәгатьләрен кайгыртучы органнар юк. Шуңа күрә Үзбәкстанда яшәүче татарларның хәле, әйтик, Финляндиядә яшәүче татарларныкыннан әллә ни аерылмый, әле начаррак булмаса ярый...

Илдәге милләтара мөнәсәбәтләрне нормаль эзгә төшерү өчен милли мәнфәгатьләрне кайгыртучы субъектларның юридик һәм фактик яктан тигез хокуклы булуы кирәк. Гамәлдәге вәкиллек системасы һәм федератив төзелеш принциплары тигез хокуклылык принцибына каршы килү белән беррәттән байтак халыкларны вәкиллек хокукыннан бөтенләй мәхрүм итә. Димәк, милли мәнфәгатьләрне кайгырту мөмкинлеге бөтенләй бирелми.

Тормыш таләпләрен искә алып эш иткәндә, илебез халыкларының хокукларын тигезләү юнәлешендәге беренче адым СССР югары органнарында яисә берәр милләт зур төркем булып яшәгән республиканың югары органнарында аларның тигез вәкиллеген тәэмин итүдән башланырга тиеш, ягъни анда һәр халыкның үз мәнфәгатьләрен кайгыртучы тигез хокуклы субъектлары булырга тиеш.

Шушы юнәлештәге икенче адым, безнең карашыбызча, төрле статустагы республикаларны бетерү һәм алар урынына автономияле һәм союздашка бүленмәгән тигез хокуклы мөстәкыйль милли республикалар союзы төзү булырга тиеш.

Өченче адым — бөтен җирдә дә мәдәни автономия институтын кертү. Ул өч төрле проблеманы хәл итәчәк: 1) җирле власть органнарында милли группаларның вәкиллеген тәэмин итүне; 2) халык мәгарифен милли телдә үстерүне; 3) шулай ук милли культураның үсүен җайга салачак.

Татарлар, урыслар кебек үк, бөтен бер милләтне тәшкил итә. Бүгенге көндә үткәрелә торган политика урысларга, кайда гына яшәмәсеннәр, бөтен бер милләт буларак үсү мөмкинлекләрен тудыра. Бу ягы белән урыс халкы башкалардан нык аерылып тора. Әмма һәр милләтнең суверенитеты халыкара документларда теркәлгән, һәм шул сәбәпле берәүләргә суверенитет тәэмин ителеп, икенчеләргә тәэмин ителмичә калмаска тиеш. Милләт суверенитеты дәүләт суверенитетыннан һәрвакыт өстен тора. Милләтнең үзбилгеләнү хокукы нәкъ менә шушы принцип нигезендә хәл ителергә тиеш. Шулай да бүгенге көндә дәүләт чикләрен яңабаштан билгеләргә тотыну бик үк дөрес булмас иде шикелле. Милләтара мөнәсәбәтләр аннан башка да бик нык кискенләште. Аннан соң бит Татарстан чикләрен үзгәртеп кенә мәсьәләне барыбер ерып чыгып булмаячак, чөнки татарларның байтак өлеше барыбер читтә торып калачак, һәм бу проблеманы барыбер башка

юл яки механизм аша хәл итү соралачак. Татар милләтенең дәүләтчелек рәвешендәге үзбилгеләнү формасы булган Татарстан Республикасы татар милләтенең суверенитетын гамәлгә ашырудагы ихтимал формаларның берсе генә әле. Дөрес, ул аның иң мөһиме, милләт язмышын хәл итүчесе. Ләкин бу форма — үзбилгеләнүнең башка бер формасы — мәдәни автономия белән тулыландырылырга тиеш. Шушы ике форманы гомумдәүләт структуралары аша берләштерү бөтен бер милләт булган татар халкының мөстәкыйль хокукларын шактый тулы итеп гамәлгә ашыра алыр иде.

В.Тишковның «Народы и государство» мәкаләсендә «дөньяда дәүләтләр милли-территориаль принцип буенча гына төзелә» дигән фикер үткәрелә, һәм автор безне совет гражданнарының шәхси хокукларын, ирекләрен үстерү, аларны тирәнәйтү юлыннан барырга үгетли; аныңча, бу юл теләсә кайсы милләт вәкиленә СССРның һәр почмагында тулы канлы тормыш белән яшәү мөмкинлеген бирәчәк. Әмма безнең дәүләт тарихы, хәтта формаль яктан милли республикаң булган очракта да, милли хокукларыңны яклау шактый авыр эш икәнен ачык күрсәтте. Ә инде территориаль яктан гына бүлә башласаң, бу, гомумән, әлеге территориядә яшәүче халыкның милли составын инкяр итүгә китерә, шул исәптән В.Тишков мисал итеп алган Горький өлкәсендә яшәүчеләрнең милли составын да. Бүгенге көндә саф территориаль бүленеш принцибын яклап милли-территориаль бүленешне кире кагу ул — зур милләт мәнфәгатьләренә генә хезмәт итү дигән сүз. СССР белән РСФСР төзелеше турында идеаль караштан чыгып та, АКШ мисалына таянып та фикер йөртергә ярамый (АКШ тарихы бөтенләй үзгә ул), бу очракта илдә барган процессларның үзләрен һәм җыелып килгән каршылыкларны күздә тотып эш итәргә кирәк. Әгәр дә бездә халыкларның хокуклары юридик һәм фактик яктан гарантияләнгән булса, ул чакта әле милли дәүләтчелек андый зур роль уйнамас та иде. Ләкин без бит үз халкыбыз мисалында территориаль бүленешнең милләтебез үсешенә, аның мөмкинлекләренә нинди зыян китерүен күреп торабыз (татарларны Татарстан белән Башкортстанга кертеп бүлү дә бит этник якны истә тотып түгел, ә экономик, политик максатлардан чыгып эшләнде).

Шул ук вакытта милли-территориаль дәүләтләр төзү белән беррәттән саф территориаль автономияләр оештыру мөмкинлеген дә бөтенләй үк читкә этәрергә ярамас кебек. Бу башлыча Русиянең үзенә кагыла, чөнки аны үзәктән торып тиешенчә идарә итүе кыен, ул децентрализациягә мохтаҗ.

Гомумән, Русия үзе һәм андагы урыс милләте шактый катлаулы хәлдә калды. Беренчедән, Сталин урыс милләтенең милли йөзен бетерергә омтылды һәм, әйтергә кирәк, күпмедер дәрәҗәдә моңа иреште дә. Без бүген радиодан ишеткән, телевидениедән караган, газета-журналлардан, китаплардан укыган нәрсәләр алар бит асылда урыс милләте культурасы түгел, ә урыс телендәге культура гына, башлыча гавам-масса культурасы. Хәтта фәнни терминология дә милли йөзнең югалуын күрсәтә. Мәсәлән, без урыс культурасыннан үзгә культураларны «милли культура» дип йөртәбез, һәм шуның белән урыс культурасын башка культуралардан аерып куябыз, шулай итеп (ирекле рәвештәме, ирексездәнме) башкалар урыс милләтенә каршы куела. Икенчедән, Русия Федерациясендә дәүләт формасы буларак урысларга хас бер генә сыйфат та сакланмаган. Әйтик, Татарстан, Башкортстан, Чувашстан бар, әмма Урыс республикасын безнең ишеткәнебез юк. Барлык союздаш республикаларның үз телевидение каналлары бар, ә Русиянең аерым каналы юк. Аннан соң Русия Фәннәр академиясе һ.б. шундый оешмалар юк. Өченчедән, урысларга мөнәсәбәте булган бөтен нәрсә дәүләт системасына тиңләштерелә; урыс теле дәүләт теленә әверелде (революциягә хәтле милли мәктәпләрдә аны өйрәнү мәҗбүри түгел иде, ә бүген ул барлык мәктәпләрдә дә мәҗбүри укытыла), КПСС ҮК Русиянең ҮК функцияләрен башкара һ.б. Нәтиҗәдә кайберәүләрдә «автономияләштерү» политикасын үткәрүдә урыслар Сталинның төп таянычы булган» дигән фикер кала, һәм шул сәбәпле милли республикаларның бюрократизмга каршы белдерелгән барлык дәгъвалары кайчакта урыслар өстенә аударыла.

Милли мөнәсәбәтләрне ил күләмендә камилләштерү урыс милләтенә дә игътибар итүне сорый. Союздаш республикаларда булган барлык структуралар Русиянең үзендә дә булырга тиеш, ә инде шундый зур территория белән әйбәт идарә итү өчен әлеге идарәнең функцияләрен үзгәртү, үзәктән идарә итүне киметү, шул исәптән Ерак Көнчыгышта, Себердә, Уралда һ.б. урыннарда мөстәкыйль регионнар оештыру кирәк, һәм аларга АКШ штатларыныкы кебек хокуклар бирелергә тиеш. Бу исә Балтыйк буенда, Белоруссиядә һәм Татарстан кебек төбәкләрдә генә түгел, ә Русиянең үзендә дә мөстәкыйль хуҗалык итү исәбенә күчүнең тормышчан адымы булыр иде.

Политик һәм экономик реформа, социаль һәм милли политиканы үзгәртеп кору илдәге халыкларның реаль ихтыяҗлары таләбеннән чыгып үткәрелә. Милли мөнәсәбәтләрне камилләштермичә торып, җәмгыятьне чын мәгънәсендә демократияләштерү мөмкин түгел. Татар халкының мәнфәгатьләре, СССРдагы башка халыклар һәм милләтләрнеке кебек үк, тугандаш халыклар гаиләсендә бергәләшеп ирекле тормыш шартлары булдыруга, дәүләтчелек, экономика, мәдәният, тел сферасында фактик тигезлеккә ирешүгә юнәлтелгән. Социаль һәм милли гаделлек принципларының практик яктан тормышка ашырылуы халкыбызга зур иҗат чыганагы булып хезмәт итәчәк.

## II. Кешелек һәм милли идея

Март аенда Чаллы шәһәрендә бер кызыклы уен үткәрделәр. Ул «Милли мәдәниятләрнең хәзерге шартлардагы үсеше һәм үзара мөнәсәбәтләре» дип атала иде. Уенда бик күп шәһәрләрдән килгән төрле һөнәр ияләре катнашты. Җанны тырнап торган сорауларга җавап булмасмы дип килгән иде алар.

Җәмгыятебезнең нинди икәне шушы уенда ачык күренде. Кешеләр беренче көннән үк аерым бер киеренке шартларга килеп эләгәләр, мәнфәгатьләре тиң булган юлдашлары белән кечкенә төркемнәргә берләшәләр һәм янып-ялкынланып үз карашларын яклый башлыйлар. Бу эшлекле уенда вакыйгалар яшен тизлегендә чиратлаша, шуңа күрә без бик аз вакыт арасында үзебезне киләчәктә нәрсә көтәчәген күзаллый алабыз.

Уеннан күренгәнчә, «Милли мәдәниятләрнең үзара мөнәсәбәте» дигән темада эчтәлек белән шәкел бөтенләй тәңгәл түгел икән. Курку һәм исән калу өчен көрәш — кешеләрнең аңын шул төшенчәләр били.

Үзгәртеп кору, тормыштагы үзгәрешләргә өмет белән бергә кешеләрдә үзләренең, балаларының, илнең, җөмһүриятнең язмышы өчен хафалану тудырды. Милләтара мөнәсәбәтләрдә бу бик ачык күренде — Кавказ, Фиргранә, Балтыйк буе, Молдавия барыбызны да төрле уйларга этәрде.

Дөресен әйтергә кирәк, бүген мәдәниятләрнең үзара мөнәсәбәте дә юк, урыс мәдәниятенең башка милли культураларга йогынтысы да юк, хәзер мәдәниятләрнең үзара каршылыгы гына бар. Милләтара мөнәсәбәтләр турында сөйләшкәндә, бу фактны һич тә истән чыгарырга ярамый. Җәмгыять күз алдында ике лагерьга бүленә. Аның берсе урысларныкы булса, икенчесе — милли культурага ия булганнарныкы. Бер лагерьдагылар тигезлек һәм гаделлекне таләп итәләр, аларга табигый милли хокукларның канәгатьләндерелүе кирәк. Ләкин теге лагерь, милли хәрәкәтләрнең җәелеп китүеннән куркып, илнең бербөтенлеген сакларга чакыра. Татарстанда милләтара тыныч яшәү гореф-гадәткә кергән, әмма аның да «милли» һәм «интер» фронтларга бүленү ихтималы күзгә чалына.

Нигә әле татарлар һәм урыслар үзләренең киләчәге өчен борчыла башладылар? Татарстанның проблемалары күз алдында — балалар ата-аналарны аңламый, үз тарихларын, мәдәниятләрен белмиләр. Урысларда үз дәүләтләренә булган ышаныч җимерелә. Хәзер инде алар бер җөмһүрияттән икенчесенә теләгән чакта күчеп йөри алмыйлар, урыс теле дә бөтен империя өчен мәҗбүри булмый башлады, димәк, эштә дә җиңел генә өскә күтәрелү мөмкинлеге юк, балаларны да илнең һәрбер төбәгендә урыс мәктәпләренә биреп булмый.

Урыслар һәр җирдә кыбырсынырга тотынды. «Балтыйк буендагы вакыйгалар Татарстанда кабатланырга мөмкинме?», «Татар телен укырга мәҗбүр итәрләрме?», «Республикадан куып чыгармаслармы?» — аларны бүген шушы сораулар борчый.

Әйе, урысларга рәнҗү, аларга рухи һөҗүм милли җөмһүриятләрдә гадәти хәлгә әверелде. Әлбәттә, бу Татарстанда ачыктан-ачык сизелми. Шуңа күрә Чаллыда үткәрелгән уенны күзәтү безнең өчен кызык булды. Андый чакта уйдагы телгә күчә бит...

Уенның беренче көннәрендә үк урыс халкын гаепләү сүзләре ишетелә башлады. Аның асылы шул: барлык халыкларны изеп торучы дәүләтнең терәге — иң күп санлы урыслар. Алар бүтән милләтләрнең язмышын үзләре теләгәнчә хәл итә. Әлбәттә, каршы якның җавабында да гаделлек төсмерләре бар: «Халык үзе гаепле була алмый. Халыкны һәм сәясәт өчен җавап бирүче хөкүмәтне аерып карарга кирәк». Төрле гаепләүләрне аеруча авыр кичерүчеләрнең җаваплары болай яңгырый: «Шәхсән минем гаебем юк, мин Егор Лигачев өчен җавап бирмим». Күп урыслар килеп чыккан хәлне системаның хасияте белән аңлаталар, ул «татарларны да, урысларны да бертигез изә». Бу җавап белән күп кенә татарлар да килешә.

Әлеге позициянең йомшак ягы бар. Билгеле булганча, урысларның демократик көчләре тарафыннан башка халыкларның мәнфәгатьләре якланмый. СССР һәм РСФСР Югары Советларының эшчәнлеге, Грузиядәге һәм Бакудагы фаҗигаләр, Балтыйк буендагы үзгәрешләргә Михаил Горбачевның мөнәсәбәте шуның ачык мисалы. Шуңа күрә урысларның гаебе турындагы мәсьәлә ачык килеш кала.

Гаепләр, билгеле булганча, таләпләр белән чиратлаша: «Татар җирендә үзегезне тыйнак тотыгыз», ягъни халык мәкалендәгечә: кунак булсаң, тыйнак бул — Балтыйк буе, Кавказ, Урта Азия өчен бу гадәти позиция. Ул үз чиратында җавап реакциясен, урысларның үз хокукларын яклау омтылышын тудыра.

Урыслар татарларны «милли проблемаларга» капланып ятуда гаеплиләр. Аларча, «милли мәдәнияткә генә сәҗдә кылу» дошманлыкка илтә. Бу очракта миллилек үзе куркыныч астында кала, чөнки мәдәниятсез милләт милләт түгел. Бәйсез милли дәүләт төзү омтылышы урысларда табигый шөбһә тудыра, алар уенча, татарлар, рольләрне алмашып, үзләре «изүчегә» әйләнмәкче булалар. Шуңа күрә урысларның күбесе унитар дәүләтне көч белән яклау ягында. «Бүленмәс һәм бердәм Русия» — алар өчен иң уңай вариант, ә милли дәүләтчелек, янәсе, яңа проблемалар гына тудырачак. «Милли дәүләттә шәхес ирке юкка чыга»,— диләр алар. Ә татарларның фикере анык: «Милли дәүләттә һәркемгә дә урын җитә».

Урыслар фикеренчә, милләт турында түгел, ә шәхес турында, аның хокуклары турында уйларга кирәк. Бу тезисны кабул итәргә мөмкин. Тик шәхес хокукларын тәэмин итәр өчен җәмгыятьнең гадел һәм тотрыклы булуы мәҗбүри, ә бу тезиста аның урынын абстракт дәүләт ала, игътибар беләнрәк караганда, ул дәүләт СССР һәм РСФСР булып чыга. Мондый дәүләт төзелеше татарларны канәгатьләндерми шул. Чөнки шәхес хокуклары нәкъ менә милләтләрнең тигез хокукы булганда гына яши ала.

Урыс демократлары, гомумән, илне милли республикаларга бүлүдән баш тартырга чакыралар. Ягъни, алар фикеренчә, Русия Штатлары төзергә кирәк. Бу позиция яхшы нияттән тугандыр, әмма ул артык беркатлы. Милли мәсьәләне дәүләтнең исемен үзгәртеп хәл итеп булмый, ул сәяси һәм икътисади хокукларны тигез итеп бүлгәндә генә хәл ителәчәк. Әгәр дә СССР җөмһүриятендә Америка штатларындагы кадәр хокуклар булса, Литвага бәйсезлек өчен көрәшергә туры да килмәс иде.

Русия Штатлары төзү фикере якын араларда берничек тә тормышка ашмаячак. Килешү төзер өчен штатларның булуы кирәк бит әле! Ә штатларның булуы өчен РСФСРны таратып һәр территориягә үзбилгеләнү хокукы бирергә кирәк. Яңа федерациягә керәселәре киләме аларның? Бу очракта Татарстан һәм Башкортстан РСФСРны түгел, СССРны сайлаячак, ә башка территорияләр мондый нәрсәгә гомумән әзер түгел, аларга әле үзләрен федерациянең субъекты итеп хис итү өчен байтак вакыт кирәк.

Мин бирредә чикләр турында бәхәсләр кубачагы хакында сөйләп тә тормыйм.

Әгәр дә Русия Штатларын «өстән» — депутатлар корпусы ярдәмендә оештырсалар, ул чакта берни дә үзгәрми. Бу инде Сталин тарафыннан тикшерелгән алым. Аерма шунда — Сталин иерархик структураларны көч белән «яраткан» (ягъни барлыкка китергән), ә безнең депутатлар хокукларны көчләп тигезләячәк. Ниятләр ничек кенә изге, мәгърифәтле булмасын, ул барыбер көчләү...

Хәер, бу юридик яктан да дөрес түгел. Союз турындагы килешүне РСФСР депутатлары түгел, ә штатларның Югары Советлары төзергә тиеш.

Соңгы вакытларда космополитизм идеясе көчәйде. Ул аеруча яшьләр арасында тарафдарлар таба. Янәсе, алар милли мәсьәләләрдән өстен торалар. Беренче карашка, бу позициянең әйбәт яклары ап-ачык күренеп тора төсле. Әгәр дә космополитизмны башка милли культураларны яхшы белә торган кеше якласа, бу позициягә сокланырга гына мөмкин. Ләкин бездәге космополитлар башка милли мәдәниятләрне түгел, хәтта үзләренекен дә юньләп белмиләр.

Авторитар система, әлбәттә, барыбызны да тигез изә. Әмма изелүчеләр арасында һәр халыкның үз урыны бар. Татарларның үз-үзен тотышы шундыйрак: «Без кемнән ким?!», «Безне 400 елдан артык издегез, инде ирек бирегез», «Союздаш республика статусы таләп итәбез». Бу елак тавышлар милли мәдәниятнең чын хәлен ачык күрсәтә. «Урыслаштыру» сәясәте аны шушы көнгә калдырды. Ләкин социаль яктан караганда, бу позиция зарарлы. Уенда катнашучыларның берсе әйтмешли, «көчсезлек изүчене үзе «чакырып» тора, шуңа күрә изелүе өчен корбан үзе гаепле». Парадокс, ләкин безнең өчен бик гыйбрәтле ул.

Хәер, зарланырга дигәндә, соңгы вакытта урыслар да бездән калышмый башлады. «Безнең хәл тагын да аянычлырак! Безне таладылар. Нечерноземьега яисә башка чын урыс җирләренә карагыз, алар нинди хәлдә?!», «Без барысына да ярдәм иттек, ә алар безгә ни белән түләде?» Рәсми белдерүләр дә шундый зарларга нигезләнгән.

Үзара зарланулар һәм һәр якның милләтара мөнәсәбәтләрдә көчсез булуы тоталитар дәүләтне тагын да көчәйтә. Дәүләтнең милләте юк. Шуңа күрә милли көчсезлек беркемгә дә файдалы түгел, ул дәүләт тарафыннан булган изүне тагын да арттыра. Таркалырга торган, идеологик һәм мораль эргәләрсез генә төзелгән дәүләт үзенең гражданнарының көчсезлегеннән файдаланырга ашыга. «Көчләү — көчсезлек ул»,— дип яза Н.Бердяев.

Милләтара мөнәсәбәтләр нинди дә булса кимсетелгән милләтләр арасында түгел, ә тулы хокуклы милләтләр арасында корылса гына сәламәт була ала.

Әйе, мәдәниятләр бер-берсеннән ераклаша. Чаллыда оештырылган уен күрсәткәнчә, аларның үзара мөнәсәбәтләре беркемне дә кызыксындырмый, һәркем үз борчуы, үз өмете белән ялгыз калган. Шуның белән бергә, позицияләр, карашлар белән танышкач, бер-берең белән янәшә яшәргә өйрәнү кирәклеге дә алга килеп баса.

Татарларның милләт булып яшәргә һәм үсәргә бердәнбер мөмкинлеге калган шушы татар җирендә безнең барыбызга да — татарларга һәм урысларга, чувашларга һәм яһүдләргә — янәшә яшисе. Шушы фикерне аңларга тырышу гына каршылыкны юкка чыгара ала.

Карашларның акрын үзгәрүе татарларның да, урысларның да аерым культурасыннан, традицияләреннән килә. Урыс дәүләтчелеге, аның идеологиясе тарих төпкелләреннән башлана. Ул башка җирләрне яулап алуга гына корылмаган. Шул яуларның зарурияпен нигезләү, аны тарихи ялганга төрү — янәсе, җиңелгән халыкларга христиан мәгърифәтен алып килү урыс дәүләтенең миссиясе — урысларның аңына тирән кереп утырган. Урыс колониаль сәясәте иң беренче булып татарларның каршылыгына очраган, алар Русиягә

«ирекле» кушылырга теләмәгән. Мәскәүнең татарларга һәм Казанга карата үткән заманнарда һәм бүген алып барган үзенчәлекле политикасын аңлау өчен бу бик әһәмиятле.

Татар иҗтимагый аңында традицияләрнең тәэсире шулай ук көчле. Мәдәниятнең бик борынгылыгы, унынчы гасыр башында ук дәүләт күләмендә ислам динен рәсми кабул итү, Көнчыгыш Аурупадагы политикага зур йогынты ясый алырлык берничә көчле дәүләте булу татарларның сәяси аңында тирән эз калдырган.

Тарихи вакыйгаларның әһәмиятен аңлау да татарларда рәсми «Мәскәү версиясеннән» шактый нык аерыла. Бу аерманы татарлар бик кимсенеп кабул итәләр, чөнки ул каршы як тарафыннан Казанның 1552 елда яулап алынуын аклауга корылган.

Ике «идеянең» асылын аңламыйча, без республикадагы милләтара мөнәсәбәтләрнең нинди кимәлдә икәнен ачык аңлый алмас идек.

Урыс иҗтимагый аңының абсолютка, җәмигълыкка (соборность) омтылуына, гомуми төшенчәләрнең хосусыйлыктан өстен торуына, ягъни бинһаялыкның нәнилектән, җәмгыятьнең шәхестән әһәмиятлерәк булуына Н.Бердяев та игътибар иткән. Чыннан да, болар «урыс идеясенең» нигезендә ята.

«Татар идеясе» исә Бөек Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы заманнарында татарларның мөстәкыйль һәм көчле булуы турындагы хатирәләр белән бәйле. Явыз Иванның Казанны яулап алу нәтиҗәсендә дәүләтчелектән мәхрүм булуларын татарлар һич тә оныта алмый. Ул тарихи һәм әдәби әсәрләрдә генә түгел, халык авыз иҗатында чагылыш тапкан. «Милли дәүләтчелекне кайтарырга» омтылу, 1552 елның 15 октябрен матәм көне дип санау — шушы хатирәләр нәтиҗәсе. Бу сәяси факт бәхәссез, шуңа аны татарларның политик аңындагы төп элемент буларак кабул да итәргә кирәк.

«Татар идеясенең» асылы Татарстанга бәйсезлек алудан тора. Сүз, әлбәттә, СССРдан аерылу турында бармый. Держава буйлап сибелгән татарлар өчен тулы бәйсезлекнең мәгънәсе юк. Аларга бер-берсе белән элемтәне ныгыту өчен СССР кысаларындагы көчле Татарстан Республикасы кирәк. Бу сәяси факт та бәхәссез, шуннан башка татарларның милли дәүләтчелек идеясен аңлап булмый.

Җәмигъльк идеясе урыс рухының державачылыгын чагылдыра. Ягъни дәүләт милли суверенитеттан өстенрәк. Бу җәһәттән держава башка халыклар тарафыннан урыс дәүләте булып кабул ителергә тиеш, чөнки СССР телдә генә федерация дип атала, асылда, монда урыс теле дә, урыс культурасы да башкалардан өстен тора.

Урысларның державачылыгы татарлар өчен үзбилгеләнү хокукының инкяр ителүе белән бәрабәр. Болай уйларга нигез бар. Сталинның раславынча, пролетариат диктатурасы өчен милли мәнфәгатьләр турында онытып торырга кирәк. «Үзбилгеләнү хокукы, — дип язды ул, — үз диктатурасын урнаштырырга хокуклы эшчеләр сыйныфы өчен киртә булып торырга тиеш түгел. Беренчесе икенчесе алдында чигенергә тиеш». Шуннан соңгы тарих, СССР һәм РСФСР Конституцияләре, экономик структура, бюджетны бүлү принциплары һәм башка чаралар Сталин тезисының исән икәнен раслады. Татарстанның бурычлары бихисап, хокуклары гына юк. Кешеләр моны бик әйбәт тоялар — әйе, Татарстанны милли дәүләт дип санап булмый. Союздаш республика таләп итүнең сәбәбе шунда.

Күпчелекнең азчылык каршында һәрвакыт хаклы булуы турындагы канун әлеге дә баягы җәмигъльктан һәм державачылыктан килә. Еллар буе безгә: «Азчылык күпчелеккә буйсына»,— дип тәкрарладылар. Сәяси карар чыгару өчен күпчелекнең фикерен белү һәм тавыш бирү тамашасын үткәрү җитә. Демократик централизм ысулы, янәсе. Бу ысул аз санлы халыклар өчен үлем диган сүз. Язмыш тарафыннан аз итеп яратылганга күрә, алар мәңге хаксыз булып яшәргә мәҗбүр.

Нәкъ менә шушы күпчелек-азчылык принцибы яшәгәнгә миграция мәсьәләләренә игътибар бик нык артты да инде. Республикада яшәүчеләр үз җирләренә килмешәкләрнең агылуына торган саен зуррак борчылу белдерәләр.

Азчылыкның күпчелеккә буйсыну принцибы татарлар өчен юкка чыгу дигән сүз. Шуңа күрә алар милли дәүләтне ныгыту юлы белән үзләренең хокукларын тормышка ашырырга телиләр. Халыкларның тигез, тиң хокуклы булырга тиешлеген тәкрарлау, үзәктәге карарларга «вето» салу мөмкинлеген таләп итү — шул инкыйраз (бетү) куркынычы аркасында.

«Урыс идеясе» үзенең асылы белән мессиан. Мәскәү — Византиянең варисы, «өченче Рим» — православие диненең үзәге. Шушы фактор урыс идеологиясенең рухында көчле чагылды. Бу традицияне большевизм уңышлы дәвам итте, чөнки Русиядә марксизм тәгълимат булуга караганда дини бер ышануга тартымрак. Урыс мессианлыгы башка халыклар өчен «өлкән туган» культы булып әверелде: «Бөек урыс халкы», «Бөек урыс культурасы», «Бөек урыс теле!», «Мин өлкән бер негр булсам да, урыс телен өйрәнер идем» — мәктәптә үк безне шул догаларга өйрәттеләр. Урыс мәдәниятенең бөеклегенә шикләнү генә дә коточкыч язык санала иде. Олжас Сөләйманов үзенең «Аз и Я» китабында урыс культурасының милли культуралар-

га йогынтысы диясе урынга үзара йогынты турында сөйләргә авыз гына ачкан иде, шунда ук башына авыр чукмар төште.

«Өлкән туган» принцибын иҗтимагый аңга дыңгычлап кертү бер хәл, ул закон булып та теркәлгән.

Үзгәртеп кору башланганчы, РСФСР Конституциясендә бөтенләй милләтләр палатасы юк иде. Ягъни милли мәсьәләләрне күпчелек урыс депутатлары хәл итте. Яңа Конституциядә бу принцип бераз үзгәртелгән килеш сакланды. 107 нче статья буенча, Милләтләр Советында урысларның вәкилләре башка халыкларга караганда (барысын бергә исәпләп) өч тапкырга артыграк. Гаҗәпләнәсезме? Укыгыз: «Күпчелек — бөек һәм илаһи. Урыс халкы бөек, һәм аның дәүләте чикләрне белми, шуңа күрә урысларның һәр гамәле бөек һәм хаклы». Конституция — урыс аңының кимәлен күрсәтүче документ, 107 нче статьяны урысларның күпчелек тавышы кабул иткән бит, ә Русиядә яшәүче башка халыклар алар өчен гади бер тарихи аңлашылмаучанлык кына.

Урыс культурасы СССРда барлык башка мәдәниятләрне томаларга тырыша. Без чит ил культураларына да «урыс күзлеге» аша карарга мәҗбүр. Шуңа җавап рәвешендә татарлар үз тарихларына борылалар, Шәрекъкә өмет белән карыйлар, шуңа күрә ислам һәм гарәп әлифбасы белән кызыксыну, башка төрки халыклар белән якынаерга омтылу... Милләт исән калырга тели.

Җәмигълык, державачылык, мессианлык белән тәрбияләнгән урыслар өчен милли хәрәкәтләр һәрвакыт «законга каршы» булып тоела. Алар уенча, мәйданга чыккан аз санлы милләт вәкилләре — тынычлыкны бозучылар, хәтта экстремистлар. Әйе, азчылыкның хокукларын тәэмин итми торып, ул һәрчак хаксыз булып күренәчәк.

Әлбәттә, урысларның кеше хокуклары турында гәп куертуы уңай — күренеш. Ләкин еш кына ул гәпләрдәге шәхес вакыттан һәм шушы яссылыктан аерым яши, ул ниндидер абстракт һәм җансыз. Шәхес хакында, билгеле, фәлсәфи яссылыктан карап та фикер йөртеп була, һәм ул аның асылын аңлау өчен нидер бирә дә кебек. Шул ук вакытта шәхесне социологик яктан өйрәнү бу очракта урынлырак булыр төсле. Маркс әйтмешли, шәхес — иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең чагылышы да бит әле, шуңа күрә аны милли мәнфәгатьләрдән гайре аңлау мөмкин түгел.

Тарихи юлларын башлаганда, урыслар өчен дә, татарлар өчен дә җәмәгатьчелек (община) зур роль уйнаган. Аерым кеше берни дә түгел... Бу традиция совет системасы өчен нигез ташы булып ятты: иҗтимагый мәнфәгатьләр хакына кеше үз-үзен корбан итәргә тиеш! Матросов исеме сугышта гына түгел, тыныч тормышта да эталонга әверелде. «Алмаштыргысыз кешеләр юк!» — бу совет тәгъбире дәүләт өчен канун иде. Кешеләр «киң массалар» дип аталды, аларны иҗтимагый хезмәт өчен яраклы соры, чырайсыз төркем итеп күзалладылар. Л.Троцкий «хезмәт армиясе» дип атаган массаларда индивидуализмның (шул җәһәттән миллилекнең дә) чалымы да калырга тиеш түгел иде. Шушы традицияләргә Явыз Иван һәм Петр патша заманнарыннан мирас булып килгән законсызлыкны, башбаштаклыкны, ялагайлыкны да өстәргә кирәк. Болар барысы бергә безнең сәяси мохитне тәшкил итә. Билгеле, мондый мохиттә милләтнең үсеше турында сөйләргә туры килми.

Урысларда һәм татарларда шәхес хокуклары милли хокуклар белән ничек яраша соң? Тарихтан күренгәнчә, аларның икесендә дә индивидуализм хөрмәттә булмаган, шәхеснең без һәрвакытта да дәүләткә, төркемгә, күпчелекнең фикеренә бәйле икәнен күрәбез.

РСФСР тоталитар совет системасының таянычы булып тора. Шул ук вакытта аны ни федератив дәүләт дип, ни милли дәүләт дип булмый. Димәк, урыслар, милләт буларак, эчке иҗтимагый структура белән түгел, ә псевдорус дәүләте тарафыннан берләшкән булып чыга. Башкача әйткәндә, алар өчен милләтне дәүләт алмаштыра. Урысларның үз фольклорына битараф булуын шуның белән аңлатырга мөмкин, аның урынын аларда «Подмосковные вечера», «Катюша», «По долинам и по взгорьям» җырлары алды һәм әле әйбәт дигәндә, чегән аһәңнәре белән баетылган элекке романслар калды.

Ләкин соңгы вакытларда урысларның милли хәяты уянуын да күзәтәбез. Төрле яссылыкларда күренә ул: Русиягә суверенитет таләп итүдә үз компартияләрен, Фәннәр академиясен, телеканаллар, газета-журналлар булдыру омтылышында без урысларның милли үзаңы бик зур үсеш алуы белән очрашабыз. Бу тенденциянең ничек тәмамлануын алдан әйтүе кыен. Миңа калса, урыс милләте географик үзенчәлекләр һәм җирле культура традицияләре нәтиҗәсендә, шулай ук базар экономикасының басымы астында берничә социаль-территориаль төркемгә таркалырга мөмкин. Хәзер урысларның берләштерә торган үзәкләре юк. Мәскәү урыс Мәккәсе түгел инде, иске идеологик төшенчәләрнең әһәмияте югалды, ә яңалары тумаган. «Урыс идеясенә» ясин чыгарга вакыт җитте. Урыслар үзләренең державасы өчен пьедесталга гасырлар дәвамында таш ташыдылар, ләкин якын арада «яңа урыс идеясе» эшләнмәсә, бу таш кыяның алар өчен кабер өстендәге курганга әверелүе ихтимал. Аларга яңа пәйгамбәрләр кирәк.

Татарлар, барлык совет кешеләре кебек үк, коллык психологиясен тудырган бу системаның бер өлеше иде. Ләкин социаль изү өстенә милли изүнең дә өстәлүе татарлардагы басынкылыкны, юашлыкны тагын да

арттырды. Күп татарлар ассимиляция политикасын баш иеп кенә түгел, алкышлап, мөкиббән китеп кабул иттеләр. Татар теленә һәм мәдәниятенә игътибарның артуына каршы «Советская Татария» газетасына ачулы хатлар язучыларның күбесен әнә шул коллык психологиясе тудырган нигилистлар тәшкил итә. Маңкортлар милли мәдәнияткә каршы бөекдержавачыл шовинистларга караганда да ярсыбрак көрәшәләр. Ленинның Дзержинский тәртибенә карата әйткән сүзләрен искә төшерик: «Урыслашкан инородецлар урыс мәктәпләрендә таякны бөгебрәк тә ташлыйлар». Әйе, урыслашкан татарларның күбесе бер үк вакытта бөекдержавачыл шовинистлар да. Бәхеткә, алар күп түгел һәм вакыт үтү белән тагын да азаер...

Милли традицияләрнең саклануы өчен көрәшүче кешеләр милләтнең асылын билгели. Ассимиляциягә һәм урыслашуга каршы чыккан бу шәхесләр бүген дә демократик хәрәкәтнең алгы сафында.

Ике милләт тә шәхеснең үсешен дәүләткә баглы рәвештә күз алдына китерә. Әмма урысларда бу — держава, ә татарларда — милли дәүләт. Позицияләрнең уртаклыгы булуга карамастан, аерма да шактый. Урыс позициясе консерватизм ягына тарта, чөнки ул хәзерге дәүләт структурасын саклауга юнәлтелгән. Милләтләрнең тигезлеген тану урыслар өчен псевдорус империясенең таркалуы һәм чын федерация төзү кирәклеген икърар итү белән бәрабәр. Андый федерациядә Урыс республикасының урыны нинди булыр? Башкача әйткәндә, «урыс идеясенең» бүген роле пассив. Чаллыда узган уенда катнашучыларның берсе юкка гына: «Сез безнең юлда бүрәнә кебек ятасыз»,— дип, урысларга булган рәнҗүен белдермәгәндер.

Татар позициясе яшәп килгән империяне җимерүгә корылган. Шуның белән ул прогрессив. Ләкин аның йомшак ягы да бар. Бәйсез милли дәүләт төзү әле шәхес хокукын тәэмин итми. Зур империянең кечкенә копиясе булмасмы ул? Шәхес иреге, гражданлык хокукларын саклау гына тоталитаризмга каршы тора ала, шул принципны таныганда гына татарларның һәм урысларның позициясе берләшергә мөмкин.

Урыслар гомумкешелек өчен иң кыйммәтле төшенчә булган кеше хокукларын байрак итүләре белән һичшиксез хаклы. «Кеше хокуклары декларациясе» — XX гасырның иң бөек документы. Шул ук вакытта милли хокукларны дәгъвалаучы татарлар да хаксыз түгел. Бу турыда да СССР кул куйган халыкара документлар бар.

Кеше хокукларын милли хокуклардан башка күз алдына китереп булмый. Аларның берсе бозылса, икенчесенә дә хилафлык килә.

Шул ук вакытта шәхес кешелек өчен иң кыйммәтле төшенчә булып кала бирә. Планетаның исән-имин калуы соңгы чиктә кеше хокуклары белән бәйләнгән. Кеше хокукларын тәэмин итмәгән дәүләт ирекле дәүләт була алмаган кебек, башка милләтнең хокукын тәэмин итмәгән зур милләт тә ирекле була алмый.

Планета күләмендә фикер йөртеп кенә милләтара мөнәсәбәтләрне җайга салырга мөмкин, һәр милләтнең, һәр культураның кешелек өчен нинди кыйммәткә ия булуын аңласак кына, без милли тарлыктан котыла алырбыз. «Планетар позициядән» карасак кына, без һәр милли үзенчәлекнең кимчелек түгел, ә нәкъ менә өстенлек икәнен күрербез. Аны инкяр итәргә түгел, ә өйрәнергә, үстерергә кирәк. Мәдәниятләрнең үзара мөнәсәбәткә керүе, бер-берсенә йогынты ясавы дөнья цивилизациясе кысаларында гына нәтиҗәле була ала.

## МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК ӘЛИФБАСЫ

### Татарстанга — союздаш республика статусы!

енә бишенче ел инде без үзгәртеп корудан ниндидер могҗиза көтәбез. СССР депутатларына, Президентлык властена, КПССның булачак XXVIII съезды карарларына өметләнәбез. Ләкин могҗиза булмаячак. Әгәр «югарыдан» инициатива көтеп торсак, без бары тик бер нәрсәгә генә — республика экономикасының тулысынча уңышсызлыкка очравына гына ирешәчәкбез. Татарстанның киләчәге өчен без үзебез, хөкүмәтебез җавап бирә. Ләкин моның өчен безнең тиешле политик хокукларыбызның булуы кирәк.

СССР хөкүмәте безгә Татарстан Дәүләт план комитеты белән бергәләп региональ хуҗалык исәбе механизмын тәкъдим итә. Янәсе, ул безгә үзидарә һәм үзфинанслау мөмкинлеген бирер, республика халкының хокукларын киңәйтер. Мин үзем бу чараларны халыкның хокукларын киңәйтү дип түгел, ә безнең хокукларны законсыз рәвештә тартып алу дип бәяләр идем. Экономик мөстәкыйльлек дип аталган нәрсәнең кайбер иң төп якларына гына күз салыйк.

Җирдән һәм табигый ресурслардан без үзебез файдалана алмыйбыз. Нефтьтән килгән долларлар үзәк органнар кулына керә, безгә исә тозланган җирләр һәм тозлы чишмәләр генә кала. Шул җәһәттән безне нинди перспектива көтә соң? Нефть тиздән бетәчәк, экологияне торгызу һәм халыкны эшкә урнаштыруның барлык проблемалары безнең җилкәгә авыр таш булып утырачак, ә ул таш Татарстан экономикасын һаман

батыра барачак. Исең китәр, үзебезнең гаять зур табигый байлыкларыбыз үз өстебезгә шулай бәхетсезлек булып төшсен әле!

Татарстанда тәкъдим ителгән үзидарә һәм үзфинанслау механизмы нормативтан тыш табышны һәм товарларны үз республикабызда калдыру мөмкинлеген күздә тота, ә менә нормаларны — дәүләт заказларын һәм лимитларны — тулысынча югары инстанцияләр билгели. Башкача әйткәндә, РСФСР безгә план күрсәткечләрен үз ихтыяры белән арттыра ала. Кайда монда үзидарә? Кайда монда халыкларның хокуклары? Юк алар!

ТАССР бюджетын РСФСР органнары билгели, өстәвенә бу елга ул 48 миллион сум дефицит белән билгеләнде. Ә бит без илгә 2,5 миллиард табыш китерәбез. Эш хакыбыз да, бурычларыбыз да менә шушы дефицит белән бәйләнгән ләбаса. Нинди гөнаһлары өчен Татарстан халкы Русия алдында мәңгелек бурычлы соң? Кайда монда үзфинанслау? Юк ул! Татарстанның РСФСР белән мөнәсәбәтләрен «вассал» (бәйлелек) мөнәсәбәтләр дип кенә әйтергә мөмкин.

Безнең экономик һәм социаль проблемаларыбызны бары тик бер шарт үтәлгәндә генә — республиканың политик статусын үзгәрткәндә генә хәл итәргә мөмкин. Хәзер республика статусы турындагы мәсьәлә гомумиләштерелгән лозунг булып түгел, ә Татарстанның мөстәкыйльлеген киңәйтү һәм ССР Союзы чикләрендә аның договор мөнәсәбәтләренә күчүе буенча байтак практик адымнар булып килеп баса.

Без балаларыбызның киләчәге өчен җаваплы. Без республиканың киләчәге өчен җаваплы. Мәскәү үз проблемаларын кайгырта. Үзәк министрлыклар һәм ведомстволар хәзер үзләренең чиксез зур аппетитлары белән трансреспублика монополияләренә әйләнеп беттеләр, предприятиеләрнең, республикалар һәм өлкәләрнең табышын умырып алырга гына торалар. Аларның комсызлыгының чиге юк.

Экономик кризистан чыгу өчен без бары тик үз көчебезгә, үз кулларыбызга гына таяна алабыз. Үз хокукларыбызны тулысынча аңларга һәм үз ихтыярыбызны ачык белдерергә тиешбез. Безнең беренче хокукыбыз — үз җиребезгә үзебез хуҗа булу. Татарстан үз җирен һәм табигый ресурсларын үз ихтыяры белән идарә итәргә хаклы. СССР кул куйган халыкара пактларда: «Бер генә халык та бернинди хәлдә дә үз карамагында булган яшәү средстволарыннан мәхрүм ителә алмый»,— дип язылган. Димәк, җиргә, нефтькә, урман һәм суларга министрлыклар түгел, ә без үзебез хуҗа булырга тиеш. Чынлыкта исә киресенчә килеп чыга. Министрлыклар җиребезне ТатАЭС, АлАЗ төзү өчен тартып алалар, уңдырышлы җирләребезне су астында калдыралар. Берсен дә бездән сорап-нитеп тормыйлар. Компенсациясе дә юк. Нефть чыгарудан, промышленность предприятиеләре һәм гидроэлектростанцияләр эшләүдән килә торган зыян бары тик ТАССРның үз исәбенә генә каплана. Безгә үзәк министрлыклар сала торган зыянны үз кесәбездән, әйткәнемчә, 48 миллион сум дефицит белән бирелә торган бюджетыбыздан чыгарып түлибез. Менә шушы мәгънәсезлекне политиклар халыкның хокукларын киңәйтү дип атыйлар.

Хәзер бу хакта сөйләшүләр белән чикләнү генә җитми. Сөйләшү күп булды инде. Җиргә һәм табигый ресурсларга милек турында Татарстан Республикасы Законы кирәк. Безнең рөхсәттән башка җирдән вәхшиләрчә файдалану булмасын, безнең рөхсәттән башка бер генә үзәк министрлык та АЭСлар һәм башка промышленность объектлары төзи алмасын, үз рөхсәтебездән башка безнең территориядә бер адым да ясый алмасын.

Аннары, без үз мәнфәгатьләребезне, үз халкыбызны, балаларыбызны үзәк министрлыклар экспансиясеннән сакларга тиешбез. Ә моны республика халкының суверен хокуклары турында закон кабул итү аша эшләргә кирәк. Мондый закон халык мәнфәгатьләренең үзәк министрлыклар мәнфәгатьләреннән өстен торуын төгәл билгеләр, промышленность төзелешен җайга салу һәм җитештерүче көчләрне урнаштыру өчен республика хөкүмәтенә вәкаләтләр бирер иде. Безнең кулда союз министрлыкларының республика халкы мәнфәгатьләренә каршы килә торган карарларын туктатып тора ала торган закон булырга тиеш.

Үзәк тарафыннан халыктан тартып алынган тагын бер хокук бар, ул — хезмәтең өчен тиешенчә алу хокукы. Без илебезгә бик зур табыш бирәбез. Әмма үзебездә торак, мәктәпләр, больницалар җитмәүдән интегәбез. Китапларны һәм музей хәзинәләрен саклар урыныбыз юк, акыл ияләребез читкә китеп бара, фәнни һәм мәдәни потенциал бик нык кимеде. Татарстан Республикасының акчасы юк, аның каравы эшләргә, эшләргә һәм тагын бер тапкыр эшләргә хокукы бар. Безгә Татарстанның бюджет мөстәкыйльлеген һәм налог инициативасы хокукын билгели торган закон кирәк. Бюджетыбызның Мәскәү чиновниклары башбаштаклыгына түгел, ә үз хезмәтебезгә бәйле булуы кирәк. Шундый законнан башка бездә бернинди үзфинанслау һәм үзидарә булмаячак.

Ниһаять, безгә республиканың экономик мөстәкыйльлеге турында закон кирәк. Ул республика экономикасында структур үзгәрешләр үткәрергә, промышленностьны кешеләргә йөз белән борырга мөмкинлек бирер иде. Безгә авыл хуҗалыгын, азык, җиңел, җирле промышленностьны, хезмәт күрсәтү сферасын, инфраструктураны үстерү өчен гадәттән тыш чаралар күрергә кирәк. Без Мәскәү аппетитына бәйсез булган эчке куллану базары булдырырга тиешбез.

Югарыда санап кителгән барлык бу законнар республиканың экономик мөстәкыйльлеге базисын тәшкил итә алыр һәм политик суверенитетны киңәйтү юлыннан алга таба ясалган гаять зур адым булыр иде.

Республиканың политик статусы үзара бәйләнгән өч нәрсәдән тора. Болар — экономик мөстәкыйльлекне, республика гражданнарының абруй-дәрәҗәсен, татар милләтенең үзбилгеләнүен тәэмин итү. Һәр өчесенең уртак тигезләүчесе бар: ул — республика белән үзәк арасында тигез хокуклы һәм үзара файдалы мөнәсәбәтләр булдыру. Менә шушы мөнәсәбәтләр договор белән нигезләнгәндә генә экономик мөстәкыйльлек, республика гражданнарының абруй-дәрәҗәсе һәм татар милләтенә ихтирам турында сүз алып барырга мөмкин. Бөтен дөньяга үзенең нәтиҗәлелеген күрсәтә торган нормаль халыкара практика менә шундый. Безнең ахыргы максатыбыз — компетенцияләрне бүлү турында Татарстанның СССР белән договор төзүе.

Кайбер иптәшләр, милләтара низаглардан куркып калып (андыйлар бигрәк тә урыслар арасында очрый), гомумән, дәүләтнең милли формаларын кире кага башладылар. Андыйлар хәзер үрнәк итеп АКШны китерәләр. Иң кызыгы шунда: Русиядә штатлар төзү идеясе — татарлар тарафыннан революциягә кадәр үк тәкъдим ителгән идея бит ул. Ләкин бүген СССРны штатларга бүлергә тәкъдим итүчеләр АКШтагы штатларның хокукларын күз алдына китерә алмыйлардыр, күрәсең. Бездә бер генә союздаш республика да Америка штатларындагыдай хокукларга ия түгел, ә инде автономияле республикалар турында әйтеп тә торасы юк. Союздаш республиканың андый хокуклары булса, Балтыйк буе республикалары да Союздан чыгу мәсьәләсен куймаслар иде. Хәер, штат кынамы соң, иң унитар дип исәпләнгән дәүләттә дә теләсә кайсы департаментның, префектура, провинция, графлыкның да хокуклары Татарстанныкыннан күбрәк. Чөнки дөньяда һәркайда департаментларның реаль үзидарәсе бар, мөстәкыйль бюджетлары һәм налоглы бар. Алар миграция процессларын үзләре җайга салып яшиләр, үз территорияләрендә җирдән һәм ресурслардан үзләре файдаланалар. Дөньяның барлык илләрендә «региональ политика» дигән төшенчә яши, бары тик Татарстанда гына региональ политиканы яклап чыгучыларны экстремистлар дип атыйлар.

Урысларның күбесен Татарстанның СССР составыннан чыгу перспективасы куркыта. Янәсе, андый очракта өлкәләр һәм республика арасында стена үсеп чыгачак. Хәтта: «Бербөтен һәм бүленмәс Русияне аергалап бетерергә юл куймабыз!» — дигән авазлар да яңгырый. Бу фикер бары тик мәсьәләгә төшенеп җитмәүгә корылган. Татарстанның мөстәкыйльлеге һич тә Русия белән элемтәләрнең йомшаруын аңлатмый, киресенчә, бәйләнеш ныгыячак кына. Хәзерге бюрократлык мөнәсәбәтләре үзара файдалы экономик бәйләнеш белән алыштырылачак. Европага күз салыгыз, анда гаять көчле интеграция процесслары бара, ә милли экономикаларның мөстәкыйльлеге һич тә бозылмый. Экономик мөстәкыйльлек бюрократлык интеграциясе өчен түгел, ә чын интеграция өчен шарт булып хезмәт итә ала. Мәсәлән, хәзер Чаллыдан Балтыйк буе республикаларына бетон әйберләр ташыйлар. Кемгә файдалы бу? Татарстангамы? Русиягәме? Балтыйк буенамы? Ул бары тик бюрократиягә файдалы. Татарстанның экономик мөнәсәбәтләре күптән инде гомумсоюз мөнәсәбәтләренә әверелде, чөнки безнең продукциянең 85 проценты гомумсоюз буйсынуындагы предприятиеләрдә җитештерелә. Менә шунлыктан РСФСР органнары хәзер безнең өчен экономик үсешне тоткарлый торган артык буын гына булып тора.

Федератив мөнәсәбәтләр халыклар арасында ышаныч урнаштыруны күздә тота. Бу ышаныч үткәннәргә дә, хәзергегә дә кагылырга тиеш. Үзәк матбугат татарларның тарихи үткәне турында ниләр генә язып бетермәде, мондый ялган стереотипларны бетерү өчен әле күп еллар кирәк булыр. Кызганычка каршы, үзәк матбугат үз ялгышларын төзәтергә җыенмый да бугай.

Карыйк әле, хәзерге, «яңартылган» Русиядә Татарстанга нәрсә тәкъдим ителә? РСФСРның яңа Конституциясе буенча Милләтләр палатасы булдырыла. Аның 107 нче статьясы нигезендә вәкиллекнең түбәндәге нормасы билгеләнә: һәр автономияле республикадан өчәр кеше, ә калган автономияле берәмлекләрдән берәр депутат. Аның каравы өлкәләр, крайлар, Мәскәү һәм Ленинград шәһәрләре барысы бергә 63 тавыш алалар, бу исә калган барлык автономияле берәмлекләрнеке кадәр. Татарстаннан — 3 депутат, ә урыс телле Русиядән — 63! Менә сиңа халыклар арасында ышаныч! Әгәр дә инде автономияле берәмлекләрдән сайланган депутатларның яртысына якыны урыслар да булса, ул чагында калган башка милләтләр белән чагыштырганда урысларның өстенлеге өч тапкыр күбрәк булачак. Мондый ныклык запасы нигә кирәк соң? Мин моны өлкән туган принцибын юридик яктан беркетү генә дип карыйм. Мондый мәгънәсез Конституция булдыру кемгә кирәк булды икән? Мондый Конституция Русия халыклары арасында ышанмаучылык хисе ояту өчен бюрократиягә кирәк булгандыр. Мондый халыклар белән идарә итүе җиңелрәк, югары постта утыруы җиңелрәк. Нәкъ менә бюрократлар бербөтен һәм бүленмәс Русия яклы. Ерак Көнчыгыш республикасы, мөстәкыйль Себер, Урал, Идел буе, суверен Татарстан һәм Башкортстан нәкъ менә шуларны куркыта.

Татарстан ни өчен союздаш республика була алмый соң? Моны бүген нигезле итеп аңлатырга мөмкин түгел. Шунлыктан каршы як түбәндәге тезисны китереп куя: «Эгоистлар» булырга ярамый, башкалар турында уйларга кирәк. Әгәр Татарстан союздаш республика булса, мондый очракта башка автономияле рес-

публикалар нишләр? Барлык автономияле республикаларга союздаш республикалар белән тигез хокуклар бирергә кирәк». Ничек кенә әйтмә, сәер логика бу. Элек Сталин халыкларга төрле статусларны көчләп таккан. Бүген без барысын да тигезләргә телибез, әмма һаман шул көчләп тагу юлы белән. Чувашлардан, марилар, калмыклар һәм башка халыклардан союздаш республика статусы кирәкме-юкмы дип сорап та тормыйбыз. Бәлки, алар моны теләмиләрдер? Нәрсә, аларны хәзер оҗмахка күсәк белән куып кертикмени? Без Әфганстанда да шул ук «изге ниятләр» белән көч ярдәмендә социализм төзергә омтылып караган идек...

Милләтләрнең тигез хокуклылыгы шунда: һәр халык үзенең политик статусын үз ихтыяры белән сайларга, кайсы функцияләрне үзендә калдырырга, ә кайсыларын үзәк органнарга бирергә кирәклеген мөстәкыйль билгели ала һәм югарыгы органнарга бирелгән функцияләрен теләсә нинди вакытта кире кайтара ала.

Ниһаять, автономияле республиканың создаш республикага күчүе механизмын кемдер беренче булып эшләргә тиештер инде.

Татарстанның союздаш республика була алу хокукын нигезләп күрсәткәндә, тарихи, экономик һәм культура ягыннан күпләгән факторлар китерелә. Дөресен әйткәндә, барлык мөнәсәбәтләр икенчел характерда гына. Монда бердәнбер критерий — халыкның үз ихтыярын белдерүе. Халыкның үзбилгеләнү хокукы халыкара договорларда, Советлар Союзының дистәләгән документында теркәлгән, хәзер вексельләр буенча түләр чак житте.

Үзәк органнарга гына түгел, безнең үзебезгә дә бер житешсезлек хас: республикабызга, халкыбызга, милли культурабызга ведомствочыл, өлкә критерийларыннан чыгып карыйбыз. Болай ярамый.

Татар культурасы — дөнья культурасының аерылгысыз өлеше, һәм үз республикабызда бара торган процессларга бездә планетакүләм караш булырга тиеш. Җир цивилизациясе милли культуралар җирлегендә үсә. Аларны бердәйләштерү мәдәниятне ярлылануга, бетүгә китерә, ә аларны төрлеләндерү, киресенчә, безне моннан коткара. Кешелек өчен кечкенә һәм зур халыклар юк — аның өчен барысы да тигез, барысы да кыйммәт. Милләтара, федератив мөнәсәбәтләрне анализлаганда без халыкара күләмдә танылган принциплардан, нормалар һәм договорлардан чыгып эш итәргә тиеш. Шунлыктан РСФСР Конституциясендә 107 нче статьяның барлыкка килүе, СССР Югары Советының автономияле берәмлекләр белән исәпләшмәве, Русиядә һәм Советлар Союзында татарларны күрмәскә тырышуы бик сәер. Татарларны Русия халкы дип кенә карарга ярамый, татарлар һәм татар мәдәнияте — гомумкешелек культурасының, гомумдөнья цивилизациясенең аерылгысыз өлеше.

Татарстан — ике зур культура: татар һәм урыс культурасы үзара янәшә яши торган республика. Политиканы билгеләгәндә шушы факттан чыгып фикер йөртергә кирәк. Тегесе белән дә, монысы белән дә санашмау политиканы уңышсызлыкка китерәчәк. Республикабыз территориясендә яшәүче барлык кешеләр өчен Татарстан — уртак Ватан, һәм безгә экономик мөстәкыйльлекне, политик суверенитетны тормышка ашыру өчен гражданлык килешүе кирәк. Татар иҗтимагый үзәге «Урыслар, Татарстаннан китегез!» дигән лозунгны гаепли. Безнең хәрәкәткә яла ягарга тырышучы провокаторлар өндәве бу. Моның максаты бер генә — урысларны Татар иҗтимагый үзәгенә каршы куйю. Без «Татарларны кыйна — Русияне коткар» дигән лозунгны да гаеплибез. Монысы да провокаторлар эше. Һәр ике лозунгны бер үк кул яза, күрәсең.

Илебез кыен идеологик кризис кичерә. Коммунизм идеяләренең дәрәҗәсе төште. Әлегә яңа идеалларыбыз юк. Безгә иске догмалардан ваз кичәргә һәм конкрет эшләр белән шөгыльләнергә, республикабызны коткару өчен ашыгыч чаралар программасы кабул итәргә кирәк. Безгә мөстәкыйльлек һәм үз республикабызны үзебез идарә итү өчен чын хокуклар кирәк.

ТАССР Югары Советының яңа составы эшне җир һәм табигый ресурслар турында законнар, республика халыкларының суверен хокуклары, бюджет мөстәкыйльлеге һәм налог инициативасы турында законнар кабул итүдән башларга тиеш. Ләкин тулысынча Югары Советка гына ышанып ятарга да ярамый. Гражданлык инициативасы кирәк. Дәүләт ул — без! Республика ул — без, аның гражданнары! Республиканың киләчәге өчен без җаваплы.

## МИЛЛИ АЗАТЛЫК ҺӘМ ДЕМОКРАТИЯ

үген СССРда икътисади, сәяси, идеологик проблемалар милли мәсьәләне хәл итүгә барып терәлә. Аны хәл итү — халыкларга үз экономикаларын, сәясәтләрен һәм мәдәниятләрен үстерү юлларын, формаларын, чараларын сайлау иреге бирү дигән сүз. Милләтнең ирекле үсешенең мөһим шарты булып милли дәүләт төзелеше тора.

Милләтләрнең үзбилгеләнү хокукы дәүләт төзелешенең априор  формаларын күздә тотмый. Аны һәр халык үзе сайлый. Шуңа күрә бер халыклар союздаш республика статусына ия булып та, икенчеләре бары

автономиягә, ә өченчеләре автономияле өлкәгә генә ия булуны билгели торган принцип юк. Үзбилгеләнү субъекты булып бары тик халык, аның ихтыяры гына тора ала.

Милли мәсьәләне хәл итү бер халыкларга кагылып та, икенчеләргә кагылмыйча кала алмый. Теләсә кайсы халык тарих алдында тигез хокуклы, шуңа күрә урысларга яки казахларга өстенлек биреп тә, татарлар яки чувашлар белән исәпләшми калу ярамый.

Минем тирән инануымча, милли мәсьәләне өлешчә генә хәл итү мөмкин түгел. Аны төрле халыкларга чиратлап бирмиләр. Империя структурасыннан иртәрәк арынып, төрле шартлар нәтиҗәсендә бәйсезлек алган халыклар булырга мөмкин. 1917 елдан соң финнар, поляклар белән шулай булды. Әмма системада калучылар бер җепкә теркәлгән. Империя системасы принцибы шушыннан гыйбарәт: ул гамәлдәге барлык халыкларны аеруча изелгән халык дәрәҗәсенә төшерергә омтыла. Бу законнан чыгармалар юк. Милли мәсьәлә хәл ителмәгән яки өлешчә генә хәл ителгән системада халыклар иртәме яки соңмы хокуксызлык җәһәтеннән тигезләшә. Шуңа күрә яисә халыклар барысы ирекле була, яисә без барыбыз да системаның корбаннары булачакбыз. Өченче юл юк.

Унитар дәүләттә халыкларның хәле аеруча изелгән халык хәленә һаман якыная бара. Бирегә чиккә якын урнашканлык та, халык саны күплеге дә, башка факторлар да ярдәм итми. Мисалга Украинаны алыйк. Революциядән соң ул кешеләре гаять күп һәм экономик потенциалы булган, географик яктан уңай урнашкан бәйсез диярлек дәүләт иде. Берни дә ярдәм итмәде. 70 ел дәвамында украиннар хокуксыз милләт хәленә төшерелде.

СССРның идарә структураларының үзенчәлеге шуннан гыйбарәт ки, анда барлык халыклар һәм республикалар эчке колония хәлендә. Мин урыс халкына да ташлама ясамас идем. Ул колонияләрне изүдән берни дә алмады, ә аның ата-бабадан калган җирләре, бигрәк тә кара туфраксыз зона аеруча нык таланды. Минемчә, бу юри эшләнде бугай. Урысларны, башка халыкларны «совет халкы» дигән төшенчә «тигезләде». Бүген үзенчәлекле урыс милли мәдәнияте үсми. Урыс республикасы юк, һәм бу Русиянең милли дәүләт төзелешен үзгәртүне, димәк ки, СССРның төзелешен үзгәртүне дә тоткарлаучы факторларның берсе. РСФСР унитар дәүләт сыйфатында яшәгәндә, илдә демократияләштерү башланып китә алмый һәм СССР халыкларын милли азат итү мәсьәләсе дә хәл ителмәячәк.

Милли мәсьәләне хәл итми торып, демократия яши аламы? Демократияне милли азатлыктан аерып карарга ярыймы? Принципта бу мөмкин әйбер түгел, чөнки теләсә кайсы демократия милли азатлыктан башлана. Демократия ул — халык власте. Халык изелгән икән, ул тарих субъекты була алмый. Милләтләр суверенитетына мөнәсәбәте булмаган демократия ялган ул. Демократия аерым халыклар өчен генә яши алмый. Ул йә бөтен кеше өчен, йә ул юк. Әгәр кемдер казахларның яисә бүтән халыкларның проблемалары татарларның проблемаларын хәл итми торып хәл ителә дип уйлый икән, ул ялгыша. Без бер җепкә теркәлгән. Без яисә кулга-кул тотынып югарыга күтәреләбез, яисә бөтенебез бергә упкынга мәтәләбез. Бөтен кешенең азатлыгы — һәркем азатлыгының шарты ул.

Тарихны искә төшерик. Мәгълүм булганча, СССРны төзү юллары төрле иде. Сталин үткәргән «автономияләштерү» сәясәте белән бергә бүтән линия дә яшәп килде. Монысы — СССРны тигез хокуклы республикалар союзы итеп, союздаш һәм автономияле республикаларга бүлмичә төзү. Бу линиянең теоретигы Мирсәет Солтангалиев иде. Нәкъ менә шушы кеше Казахстан (ул чагында Кыргызстан) һәм Төркестан республикаларын төзү зарурлыгын яклап чыкты. Әгәр ул шул дәрәҗәдә принципиальлек күрсәтмәгән булса, бүгенге көндә Казахстан, Кыргызстан һәм Урта Азия республикалары, ихтимал, РСФСР составындагы автономияле республикалар булып калырлар иде. Ул Көнчыгышның Рыскулов һәм башка җитәкчеләрен бөтен кешедән дә ныграк яклады. Солтангалиев Башкортстан Республикасын һәм башкорт халкын җан-фәрман яклаган. Зәки Вәлидине яклаган бердәнбер кеше булгандыр. Мин бүген Казахстан, Үзбәкстан, калган союздаш республикалар җитәкчеләренең килешү төзү процессында Татарстан тоткан позиция белән ризасызлыгы хакында ишетеп торам. Алар безнең республиканың башкалар белән тигез булырга омтылуын хупламый, без 70 ел буе көрәшкән статусны танырга теләми. Моны күреп бик гарьләнәм. Кеше хәтере шулкадәр дә игелексез була алыр икән. Кешеләр үз тарихларын тиз онытала́р, алар бәхете хакына ачыктан-ачык Сталинга каршы чыккан һәм үлемгә барган кешеләрне шулай тиз онытала́р икән. Егерменче елда ук Солтангалиев Төркестанга «дәүләтчелекнең элементар нигезләрен» бирүне таләп иткән. Ягъни Төркестан коммунистлар партиясен, Төркестанның җирле кызыл армиясен, мөстәкыйль дәүләт бюджетын булдыруны һ.б. таләп иткән. Ул 1923 елда болай дип яза: «Әлбәттә, миңа каршы төшәрләр, өйрәтеп маташырлар — имеш, бу «пантюркизм»га, Туран дәүләте төзүгә китерер, аңа янәшәдәге башка төрки территорияләр: Кыргызстан, Кашгар, Хива, Бохара җирләре, Әфганстан һәм Иранның төрки халыклар яшәгән җирләре кушылыр. Халыкара социаль революция мәнфәгатьләре күзлегеннән караганда моның нәрсәсе куркыныч соң?!»

«Бу урыс милләтчелеге өчен куркыныч. Бу Көнбатыш Европа капитализмы өчен куркыныч. Ә революция өчен бу куркыныч түгел». Солтангалиев беркайчан да колониаль һәм милли мәсьәләне аерып карама-

ды, чөнки ул милли окраиналарны Русиянең эчке колонияләре итеп карады. Солтангалиевнең гаять зур казанышы да, шул ук вакытта аның зур фаҗигасе дә шунда: ул милләтләрнең һәм аларның дәүләт төзелмәләренең тигезлеген яклап көрәште. Милли үсешне ул, партиянең рәсми линиясеннән аермалы буларак, котылгысыз һәм прогрессив күренеш итеп карады һәм «дәүләт организмы буларак Русиянең берничә мөстәкыйль дәүләткә таркалуының тарихи котылгысызлыгын» алдан күрде. Ул «бу таркалу үткәндәге күпсанлы дәүләтләр: Рим империясе, Гарәп дәүләте, Чыңгызхан һәм Аксак Тимер империяләре һәм Госманлы төрекләр империясе бетү рәвешендә булачак» диде. Бу вакытта ул СССРның дәүләт төзелешен Украина белән беррәттән СССРга керәчәк зур федератив берләшмәләр төзү рәвешендә күрде. «1. Урал-Идел Совет Социалистик Республикалар федерациясе, аның составында Башкортстан, Татарстан, Мари өлкәсе һәм Вятка өлкәсе булырга тиеш. 2. Гомумкавказ Совет Социалистик Республикалары һәм өлкәләре федерациясе. 3. Союз берәмлеге буларак Казахстан. 4. Урта Азия яисә Үзбәкстан, Төркмәнстан, Кыргызстан, Таҗикстан кергән Туран республикасы булыр».

Солтангалиев фикеренчә, РСФСР Себер, Урал, Үзәк-Промышленность районы, Урта Идел өлкәсе, Түбән Идел өлкәсе һәм башкалар кергән федерация булып калырга тиеш булган. Федератив мөнәсәбәтләрне әнә шулай кору, Солтангалиев фикеренчә, элек изелгән милләтләрнең урыс пролетариаты белән ныклы союзын тәэмин итә алган булыр иде. Ул егерменче еллар башында шундый идеяләр белән чыга. Ул республикаларны союздаш һәм автономияле республикаларга бүлүгә каршы була, аларның СССР составына тигез хокукларда керүен таләп итә. 1923 елда ул кулга алына, ә 1940 елда атыла.

Шундый охшашлык игътибарны җәлеп итә: СССРны төзү концепциясендә Андрей Сахаров идеяләре Солтангалиев идеяләре белән тәңгәл килә. Беренчедән, Сахаров барлык республикаларны һәм халыкларны булачак яңартылган союзның тигез хокуклы субъектлары итеп карый, икенчедән, ул Урыс республикасын штат хокуклары бирелгән дүрт зур регионга бүлүнең тарафлары була, өченчедән, ул чын демократ иде. Кызганычка каршы, Русиядә Сахаров тарафдарлары, аның вафатыннан соң, Сахаровның СССРның милли дәүләт төзелешенә кагылышлы гаять мөһим идеяләреннән баш тарттылар. Демократия йөзен үзгәртә башлады. Сәясәттә бу еш очрый торган күренеш. Большевиклар да бит әүвәл демократлар иде, бөтенесе сталинчылык белән төгәлләнде.

Тарих сабаклары гыйбрәтле. Сталинның империячел политикасы нидән башланганын искә төшерик. Ул Солтангалиевне кулга алудан башлана. Троцкий сүзләренә караганда, Сталинга каршы көрәштә аларның беренче ялгышы Солтангалиевне Милләтләр халык комиссариатыннан һәм партия Үзәк Комитетыннан чыгаруга юл куюдан гыйбарәт. «Ул тәүге кат кан тәмен тойды»,— дип яза бу турыда Зиновьев. Шуннан соң Сталин халыкларны сортларга аеруга ирешә: союздаш һәм автономияле республикаларга, автономияле өлкәләргә һәм округларга бүлә. Аның өченче адымы союздаш һәм автономияле республикаларны өлкә дәрәҗәсенә төшерү булды. Дүртенчесе — ул тулы бер халыкларга карата геноцид сәясәте үткәрде, байтак дәүләт төзелмәләрен бетерде һәм, ниһаять, барлык халыкларны милли үлеп бетү чигенә җиткерде. Бу сабак күп нәрсәләр хакында сөйли. Әгәр кайсыдыр бер моментта без үзебезнең милли хокукларыбызны гына сакларга омтылып башка халыклардан йөз чөерсәк, үз азатлыгыбызны башка милләтләр азатлыгыннан өстен куйсак, ахыр килеп, без, гомумән, барлык хокукларыбыздан мәхрүм калачакбыз. Бер генә, хәтта иң аз санлы халык та изелгән дәүләттә иртәме-соңмы барлык халыклар да изеләчәк.

Бүген союздаш республикалар үзәккә каршы сугыш ачты. Бу вакытта РСФСР союзник итеп карала, ә Ельцин демократ итеп бәяләнә! Русиянең демократиясе нидә? Качышлы уйнауда.

Егерменче елларда, СССР төзелгәндә, Русия структураларыннан үзгә союз структуралары төзү омтылышы ясалды. Без бу процессның ни белән тәмамлануын беләбез. Русия министрлыклары чынында союз министрлыкларына әверелде. Шушы юлны кабатламас өчен Русия үз дәүләт структурасын федератив нигездә төзүгә күчәргә һәм империя амбицияләреннән баш тартырга тиеш. Ельцин Татарстанга килгәч болай дигән иде: «Суверенитетны үзегез теләгән кадәр алыгыз». Хәзер ул сүзләреннән баш тарта. Аның милли сәясәтендәге мондый борылыш демократиядән баш тарту дигән сүз. 1936 елда Татарстан делегациясенең республиканы Союзга союздаш республика сыйфатында алуны таләп итүенә Сталин болай дип җавап биргән иде: «Татарстан, арка чокырын күрмәгән кебек, моны да күрмәячәк». Сталинның бу адымы үзенчә дөрес иде, ул совет империясен бүтәнчә төзи алмас иде. Русияне унитар дәүләт сыйфатында саклап калып, ул Русия структураларын союздаш республикаларны совет колонияләре хәленә төшерү өчен файдаланды, бүгенге көндә исә Татарстан Русиядәге демократияләштерү процессларына ачкыч булып тора, әгәр Русия унитар дәүләт булып сакланып кала икән, элекке хәлгә кайту котылгысыз. Демократия аерым кешеләр өчен генә була алмый. Яисә барлык халыкларның тулы азатлыгы, яисә элеккеге унитар дәүләткә кире кайтып төшү. Демократия һәм милли азатлык тәңгәл төшенчәләр.

## БӘЙСЕЗЛЕК САКЧЫСЫ — ХАЛЫК

### Мөстәкыйль Татарстан: алда безне ни көтә?

оссия демократларының җиңүе Союзның тәмам таркалуына китерде. Илебез элекке союздаш республикаларны мөстәкыйль дәүләтләр буларак тану, милек һәм армияне бүлешү өчен күчеш чорына керде. Татарстан бу хәлгә әзер түгел иде. Әгәр башка автономияле республикалар Татарстан юлыннан китсәләр, ул чагында яңа Берлек оештырырга булыр иде. Әмма күпчелек автономияләр «бердәм һәм бүленмәс» Русия составында калуны кулайрак күрделәр. Союз таркалды. Безнең республика РСФСРдан чыкмады, «бердәм һәм бүленмәс» Русия составына кермәде, РСФСР белән килешү төземәде — елның йомгаклары менә шундый.

Соңгы айда атом-төш коралына контрольне дә кертеп, Русия Үзәкнең барлык функцияләрен үз кулына алды. Б.Ельцин абруен ныгытты, ә демократлар партиясе үзенең оешмаларын барлык өлкәләргә һәм республикаларга таратты. РСФСР Президентының указлары һәм законнар Русияне хокукый яктан шулкадәр алга этәрде ки, хәзер Татарстанга аның белән тартышырга авыр булачак. Хокукый артталыкны исәпкә алсак, суверенлыкның юкка чыгу куркынычы туды.

Кризистан чыгу өчен хәзер республиканың интеллектуаль һәм сәяси көчләрен ныклап эшкә җигәргә кирәк. Моның өчен башта идарә структураларын үзгәртергә һәм кадрлар составын карап чыгарга кирәк. Тагын шунысын да әйтик, безнең җитәкчеләр хәзергә власть кризисының бөтен нечкәлекләрен аңлап җиткермиләр. Югыйсә политология законнары буенча бу хәл кардиналь реформаларга яисә властька башка сәяси көчләрнең килүенә китерәчәк.

Кызганычка каршы, республика җитәкчеләре өчен төрле яктан әйтелгән тәнкыйть фикерләре нәтиҗә ясау, прогресс чыганагы булып өлгермәде әле. Алар тәнкыйтьне шәхесне кимсетү дип карыйлар. Британия парламентында, мәсәлән, оппозиция башлыгын тәнкыйтьләгән өчен бюджеттан акча түләнә. Шунысын да әйтергә кирәк, Министрлар Кабинеты әгъзаларының эш хакы күләмендә түләнә. Алга киткән илләрдә тәнкыйть кыйммәт тора. Ә бездә тәнкыйтьләсәң, фатир ала алмыйсың, адәм рәтле эшкә дә урнаштырмыйлар.

Моңарчы Татарстанда политика профессиональ әзерлек таләп итүче сферага әверелмәде әле. Ул һаман да административ идарә аппаратының бер өлеше буларак буталып йөри. Политологлар бары тик аерым консультацияләр бирү юлын гына кулланалар.

Республикадагы сәяси хәл тиз үзгәрә. Ул гомумсоюзны һәм Русияне кабатламый. Шунлыктан, идарә аппараты дәүләт карарларын кабул иткәндә, бу эшкә анализ ясый алырлык белгечләрне дә катнаштырырга кирәк. Үз тирәсенә дус-ишләрен генә туплаган Президент уңышка ирешә алмый. Аның эш башында утыру вакыты да чикләнә. Министрлар Кабинеты һәм Югары Совет Президиумы турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Бүгенге кризистан чыгу өчен ныклы әзерлекле кешеләр кирәк. Күпсанлы киңәшмәләр, озак уйланулар өчен вакыт юк. Шунлыктан Президент указлары һәм Министрлар Кабинеты карарларын бик тиз әзерләү сорала. Закон проектларын әзерләү өчен киләчәктә килешү нәтиҗәсендә күпсанлы белгечләрне тартырга туры киләчәк.

Эшне нефтьне национализацияләү турындагы указдан башлау кулай булыр. Чөнки безнең мөстәкыйльлекне нефть коткара алачак. Нефтьнең бердәнбер хуҗасы — республика халкы. Үзәк таркалган, ә Русия барлык байлыкны үз кулына тупларга өлгермәгән шартларда без бу эшне тиз башкара алабыз. Фетнәчеләрнең җиңелүеннән соң хәрби көчләрне дә кулланмаслар дип уйларга кирәк. Нефть безнең өчен — икътисадны үзгәртеп коруның, халыкның тормыш хәлен яхшыртуның, чит илләр белән бәйләнешне ныгытуның нигезе. Безнең мөстәкыйльлекне танымасалар да, нефть милли мәдәниятне үстерүнең нигезе булачак. Русия Федерациясе һәм башка республикалар белән сөйләшү алып барганда да без нефтькә таяна алабыз. Властька ия булырга теләгән кеше нефтьне дә үз кулына алырга тиеш. Б.Ельцин моңа әзер. М.Шәймиев әзерме соң?

Милли банк булмавы да — республиканың зур кимчелеге. ТССР җитәкчеләре республиканың талануы белән ни өчендер килешеп яшиләр. Финанс мәсьәләләрен көйли алмаган хөкүмәткә ышаныч кими. Базар мөнәсәбәтләренә күчкәндә, акча икътисадның төп өлеше һәм иң зур политика булып тора. Бурычларны түләү чоры үтте инде. Бүген Финанс министрлыгы — сәяси орган. Ул үзенең исемен акларга һәм кылган гамәле өчен җавап бирергә тиеш.

Икенче зур адым — хокук саклау органнарын ныгыту. Күп кенә республикаларда Эчке эшләр министрлыгы һәм Дәүләт иминлеге комитеты җирле буйсынуга күчте. Бездә дә моны эшләргә кирәк. Бүген безнең гражданнарның эше буенча РСФСРның Югары суды шөгыльләнә. Эчке эшләр министрлыгы РСФСР бое-

рыгы буенча һәрбер сәяси лидерны, җирле органнар белән килешеп-нитеп тормыйча, Мәскәүгә озата һәм анда суд оештыра ала. Бүгенге авыр, шомлы көннәрдә моның суверенлыгыбыз өчен никадәр куркыныч икәнен аңлатып торуның кирәге юктыр.

ТССР эчке эшләр министры С.Кирилов, тартынып-нитеп тормыйча, үзенең РСФСР әмерен үтәргә торуын белдерде. Фетнә көннәрендә генә дә ул берьюлы ике тапкыр закон бозды. Башта биш егетне ябып куйды, аннары, суд карарын көтеп тормыйча, аларны азат итте. Ә законнарның үтәлешен ныклы күзәтчелек астына алырга тиешле ТССР прокуроры О.Антонов ни өчендер министрны җавапка тартырга батырчылык итми. Республиканың хокук саклау органнары йомшак эшли. Рэкетирлар һәм бандитлар Татарстанда үзләрен бик иркен хис итәләр. Хәтта эш шуңа барып җитте ки, көпә-көндез «демократик» матбугат вәкилләре катнашында участок милиционеры Татарстан халык депутаты Р.Зариповны тентергә, кулларын каерырга кереште. Бу хәлгә республика Югары Советы да тиешле бәяне бирмәде. Ни өчен соң суд прокуратура хезмәткәрләре хулиганны тәртипкә чакыра һәм җавапка тарта алмадылар? Менә шуңа күрә дә безнең мөстәкыйльлекнең якланмавы һәм халык тарафыннан сайлап куелган Президентка төрле яла яккан кешеләрне вакытында җавапка тарта алмау гаҗәп түгел.

РСФСР Югары Советы фетнә көннәрендә ТССР Президентының тәртибен тикшерергә җыена. Бу инде республикабызга аның мөстәкыйльлегенә турыдан-туры янау. Русиянең безнең эчке эшләргә тыкшынырга хакы юк. Туктаусыз Мәскәү сәясәтен үткәрүче Русия демократлар партиясе үз хуҗаларыннан акча алып тора, ә моны республикада беркем дә контрольдә тотмый. Республикадан РСФСР Югары Советына сайлаган депутатлар да үзләренең мандатларын саклап калу турында уйлыйлар. Ни өчен соң шушы көнгә кадәр аларның берсенең дә горурлыгы уянмады? Уйланырга урын бар монда.

Татарстанга И.Силаевның телеграммасы килде. Ул һәр җирдә Русия флагларын элүне тәкъдим итә. Әгәр ТССР Югары Советының Татарстан символларына ачыклык кертергә көче җитмәсә, бу эшне халык үзе хәл итәчәк. Һәр өйгә өч төсле РСФСР байрагын элә башлаганчы, балконнарга үзебезнең кызыл-яшел төстәге флагларны урнаштырырга кирәк. Комиссия тарафыннан тәкъдим ителгән арыш башакларыннан һәм ярым айдан торган герб урынына болгар ханлыгында ук һәркемгә яхшы таныш булган «Зилант» образын чагылдыручы гербны гамәлгә кертү кулай булыр. Ул безнең күптәнге традицияләребезне чагылдыра. Аны күптән инде татарлар, урыслар һәм башка халыклар кабул иттеләр бит.

Республика җитәкчеләре ни эшләргә белмичә баш ваткан бер вакытта, республиканың милли гвардиясе оеша башлады. Югыйсә бу эш белән беренче чиратта республика хөкүмәте шөгыльләнергә тиеш.

Илдә бара торган хәрби көчләрне үзгәртеп корулар, әлбәттә, Татарстанга кагылмый калмас. Союз армиясе хәзер республикаларга таркала, ә алар үзләренең милли гвардияләрен төзиләр. Татарстан территориясендә урнашкан хәрби частьлар РСФСРга буйсына. Казахстандагы һәм Украинадагы атом-төш кораллары киләчәктә кайда урнашыр? Татарстаннан алынган солдатлар кайда хезмәт итәр? Бу мәсьәләләр белән ТССР Оборона министрлыгы шөгыльләнергә тиеш. Татарстанны атом-төш коралы булмаган республика дип игълан итү һәм хәрби частьларның урнашуын ныклы күзәтү астына алу — халык таләбе. Әгәр бу эш белән ТССР Дәүләт инспекциясе шөгыльләнмәсә, моны халык ополчениесе үз өстенә алачак.

Халык бердәм булганда гына көчле. Соңгы көннәргә кадәр республикада төп көч булып КПССның Татарстан партия оешмасы торды. Яхшымы-начармы, ул оештыру функцияләрен үтәде. Бүген ул юк инде. Сәяси аренада Русия демократлар партиясе, Татар иҗтимагый үзәге, «Иттифак» партиясе, Президент һәм республика хөкүмәте калды. Киләчәктә КПССның республика оешмасы урынына, мөгаен, ике яки аннан да күбрәк партияләр туар. Алар бүгенге власть органнарына оппозиция булып торалар. Хәзергә меңнәрчә коммунистларның язмышы җитәкчеләрне аз кызыксындыра. Алар төп игътибарларын милек бүлүгә юнәлттеләр.

Минем карашымча, киләчәктә социаль-демократик юнәлештәге, халык мәнфәгатьләрен яклаучы, мөстәкыйльлекне ныгыту өчен тырышучы партия өстенлеккә ирешер. Республика партиясен төземи торып, безгә сәяси һәм икътисади кризистан чыгу, мөстәкыйльлекне саклап калу авыр булачак.

Республика бәйсезлеген саклауның яңа чоры башланды. Аның төп сакчысы — халык. Декларация кабул ителүгә бер ел үтсә дә, онытмыйк: без мөстәкыйльлегебез өчен көрәшнең башында гына әле.

## ИМПЕРИЯНЕҢ КОЯШЫ БАТКАНДА

*(Милләт һәм дәүләт турында уйланулар)*

### Кереш сүз

инозаврлар үлеп юкка чыккан сыман, империяләрнең дә гомере мәңгелек түгел. Теләсә нинди империя дә ул төрле халыкларның, аларның мәдәниятләренең, җирләренең ясалма бер кушылмасы булып тора, анда табигый бөтенлек булмый, шуңа күрә дә, аның мәркәзенең (үзәгенең) көче хәлсезләнүгә, ул төрле-төрле кисәкләргә бүлгәләнә башлый, һәм иң элек ул милли, ә аннары территориаль яктан да таркалырга тотына. Аурупа мондый үзбилгеләнү дәверен кичергән инде. Әүвәлге Госманлы һәм Австро-Венгрия империяләреннән Югославия, Болгария, Чехословакиядәге милләтара проблемалар гына торып калды. Бу яктан караганда Русия әле үзе бер ачылмаган дөнья кебегрәк. Ул иске колониаль Аурупаның торып калган соңгы баганасы дияргә була.

Яңа XXI гасырга керер алдыннан кешелек дөньясы коллыктан тәмам котылырга тели шикелле. 1917 елгы инкыйлабтан соң Русия, үзендә көч табып, империясен совет нигезенә корып торгыза алды алуын. Төрле халыкларның милли мәдәниятләре, диннәре белән каты көрәш, урыслаштыру, бөтен-бөтен халыкларны юкка чыгаруга кадәр барып җиткән ассимиляция, марксистик идеологияне көчләп тагу, иҗтимагый тормышны вә фикерне бер генә төрле итеп кору, республикалардагы администрацияне турыдан-туры үзәктән билгеләүләр милли ирекне буып килде. Сәяси һәм идеологик кыршаулар юкка чыккач, халыкларның милли җегәре уянып, алар кымшана башладылар, үзләренең тарих субъектлары икәннәрен күреп, алар үз мәнфәгатьләрен үзләре кайгыртырга тотындылар, Мәскәү фәрманын көтеп тормастан, мөстәкыйль үсеш юлларын үзләре билгеләргә керештеләр.

Русиянең әле яңа туып кына килә торган демократиясе шулхәтле күп телләре, диннәре, мәдәниятләре булган, гасырлар буе кимсенеп яшәгән, Мәскәүнең тагын да алдамасына инде тәмам өметен җуйган халыкларга нәрсә әйтә ала соң бүген, нәрсә тәкъдим итә ала? Асылда, бернәрсә дә тәкъдим итә алмый шул...

Бу юлы Русия милли территорияләрне үз кулында тотып кала алырмы, алмасмы? Башкача әйтсәк: коллыктан котылу гамәле Русиянең үз эченә керсә, ни дәрәҗәдә кергән? Шушы мәсьәләнең ничегрәк хәл кылынуына карап, илдәге генә түгел, Аурупадагы, хәтта дөньядагы хәлләр дә төрлечә үзгәрергә мөмкин.

Бүген инде әүвәлге Союз республикаларын Русия канаты астында тотып булмаячагы көн кебек ачык. Димәк ки, империя төсендә СССР бетте, дип ышанып әйтергә була. Әмма Русия Федерациясенең тамыры ныграк әле.

Русиянең, империя буларак, үз хасиятләре бар. Әгәр дә Урта Азия республикалары классик колониаль сәясәт кысаларында торган булсалар, Русиядә гасырлар буе янәшә яшәү дәверендә халыклар бик нык аралашып та, кушылып та беткәннәр. Фәкыйрьлек һәм хокуксызлык ягыннан республикалар гына түгел, урыс өлкәләре дә ярым коллык дәрәҗәсенә төшкәннәр. Ә Мәскәү (һәм аның йөзләрчә министрлыклары) үзен метрополия дип тоя башлады.

Русия түрәчелеге турында аерым әйтеп үтмичә булмас. Бу дәүләттә ул гомер буе паразит булып килде. Сәбәбе — аның бер сыйныф сыман күпсанлы һәм привилегияле булуында. Ул, дәүләт эчендәге бер дәүләт кебек булып, барысын да изеп яшәде. Урыслар исеменнән чыгып эш итсә дә, изелгән халыкларга гына түгел, урысларның үзләренә карата да коллык режимы тудырган өчен җаваплылыкны үз өстенә ул алырга тиеш. Петр заманыннан алып Русия, үзенә борылып карарга да онытып, һаман Аурупага муенын сузып килде. Түрәләрне шуннан алдырды. Алары каннары белән дә, җаннары белән дә Русия кешесе булмагач, урысның да, башка милләтләрнең дә мәнфәгатьләрен караудан ерак тордылар.

Җәмгыять демократлашканда, империянең саклануы мөмкин түгел. Демократия Русияне кызганыч хәлгә куйды. Ул «бердәм һәм бүленмәс» дигән лозунгны тәшвишкә төшерде. Патша империясе монархия принциплары таләп иткәнчә көчкә таянып кына яшәп килде. Совет империясе дә көчкә таянды, һәм аның халыкларны көчләвен аклый торган идеологик коралы «пролетариат диктатурасы» дигән сафсата булды. Яңа килгән җитәкчеләр, демократия принципларын корал итеп алып, иске нигезләрне җимерделәр һәм шуңа бәрабәр рәвештә тиешле нәтиҗәсен дә алдылар — илләре таркалды. Демократия хокук чыганагы итеп көчне куллана алмый, ул халык фикерен ачыклауны таләп итә, шул исәптән милли-дәүләтчелек өлкәсендә дә. СССР чикләре генә түгел, Русия Федерациясенең дә чикләре даимилеген җуеп бара, әүвәлге хокук нигезләре юкка чыкты, теге чактагы конфигурация бары тик тарихи традицияләр аркасында гына сакланып тора. Әмма бу хәл беренче прецедентка кадәр генә дәвам итә ала. Татарстан һәм Чечен республикаларының бәйсезлеге, Курил утрауларының Япониягә кире кайтарылу ихтималы дәүләт корылмасының ныклыгын сыный. Башкача әйткәндә, Русия Федерациясе чикләрендәге Русия — СССР чикләрендәге БДБ кебек үк тотрыксыз организм. Бу проблема инде күптән ишек шакыса да, Русия җитәкчеләренең бу гаять катлаулы мәсьәләне аңлап җиткергәннәре юк әле.

Русия урыс булмаган халыкларның милли хокукларын тәэмин итә ала торган ил түгел. Шуңа күрә заманыбызның иң төп мәсьәләсе булып төрле милли территорияләрдә яшәүче халыклар мәнфәгатен гарантияли торган дәүләтләр булдыру тора. Монда дәүләтнең әүвәлге исеме бик тә томанлы булып чыга.

Нәрсә ул Русия? Элегрәк аны СССР дип карыйлар иде. Шул империя чикләрендә урыс халкының үзбилгеләнүе үтте. Хәзер Русия Русия Федерациясе белән тәңгәлләштерелә башлады. Татарстан белән Русия Федерациясе һич тә тәңгәл күренеш түгелләр. Алай булгач, Русия Федерациясе чикләре кайда бетә дә аларны билгели торган юридик нигезләр кайда соң? Демократлашу шартларында урыс халкының үзбилгеләнүен ничегрәк аңларга икән? Урыс милләте үз язмышын үзе көчеп килгән республикалардагы төп халыклар белән бәйләрме, әллә Русия Федерациясе чикләрендәге империясен сакларга тырышырмы? Сорау өстенә сорау...

Урыс демократлары тоталитар структура катламнарын саф демократия категорияләренә кертеп каралмакчылар, милли мәсьәләне, гомумән, демократлашу проблемасы белән алыштырмакчылар. Моңа охшаган нәрсәне 1917 елны тарих күргән иде инде. Большевиклар демократия һәм Русиядәге бөтен халыкларның милли үзбилгеләнүе, тигезлеге һәм суверенлыгы турында лозунглар игълан иткән иделәр. Ә инде чын хокуклар турында сүз кузгалгач, «халыклар төрмәсен» яңадан торгызуны артыграк күрделәр. Русия демократлары да большевиклар эзеннән бара, аерма шунда гына — большевиклар, тигез хокуклар һәм үзбилгеләнү турындагы лозунглар белән башлап, «бердәм һәм бүленмәс Русия» принцибына килеп чыккан булсалар, демократлар ахырдан тотындылар да, әле кая барып чыгасыларын белгән кеше юк...

Ошаса да, ошамаса да, миллилек социальлектән өстенрәк тора. Литва, Латвия һәм Эстониянең аерылып чыгуында социаль мотивка, демократия проблемаларына караганда шул илләр халыкларының милли мәнфәгатьләре ныграк роль уйнады. БДБ халыклары демократия дигәннән барыннан да элек милли азатлыкны аңлыйлар. Аларны милли мәнфәгатьләрдән тыш саф демократия лозунглары белән алдап булмаячак. Август путчы вакыйгаларыннан бөтен республикалар да Русия белән якынаю өчен түгел, ә киресенчә, мөстәкыйльлек, бәйсезлек игълан итү өчен файдаланганнар икән, бу бит юкка гына түгел иде. Алга таба да Русиянең хәлсезләнүеннән милләтчеләр үзләренең дәүләт үзбилгеләнүе өчен файдаланачаклар һәм моны мәскәүлеләр аңлавындагы саф демократия белән бәйләп азапланмаячаклар.

Бер генә халыкның да әле үз хокукларын көрәшсез-нисез генә ала алганы юк. Аерма булса, шунда гына булыр: бер халыклар бәйсезлекләрен танытуга бераз тынычрак юл белән ирешә алган булсалар, күпчелек халыклар үзбилгеләнүләренә каннарын коя-коя бардылар. Соңгы елларда БМОның булуы ярдәм итә итүен, әмма аның да мөмкинлекләре чиксез түгел. Аннары бу халыкара җәмгыятьтә күп кенә халыкларның җир йөзендә яшәп ятканнарын да белеп бетермиләр әле...

Әүвәлге СССР империясе җирләрендәге милләтара мөнәсәбәтләр, яман төс алып, төрле илләрнең һәм бөтен дөньяның тынычлыгын ала. Көнбатыш политологларының иң өметсез фаразлары да дөрескә чыкты — совет империясе сүтелде дә төште, кешеләрнең аңын бутап, халыклар арасына булмаган киртәләр корды, республикалар һәм кешеләр арасына суык җибәрде. Көнбатышта бик көткән көннәр килде: совет империясенең җимерелүе дөньяда көчләр торышын үзгәртте, дөньяда бер генә олы дәүләт — АКШ кына торып калды. Ә бу хәл халыкара сәясәттә яңа тенденцияләр ачмый калмас һәм дөньяда урнашкан мәгълүм бер тәртипне дә бозуы ихтимал.

Җир шарында бездә бара торган низагларны игътибар белән күзәтеп, аларны локальләштерү турында борчылалар. Балтыйк буе республикалары сыман башкалар да тынычрак кына аерылып чыга алырлармы, әллә Сербия-Хорватия конфликтлары килеп чыгармы? Аурупа белән Азиядә атом-төш кораллары булган Украина һәм Белоруссия аерылып чыккач, нинди үзгәрешләр булыр? Урта Азиянең мөселман республикалары һәм Азәрбайҗан үзләрен ничек тотар? Хасил булган вазгыять Русия Федерациясенең бөтенлегенә, аерым алганда, мөселман Төньяк Кавказына, мөселман-христиан Татарстанына вә Башкортстанына нинди йогынты ясар? Сораулар, сораулар... Һәм аларның һәркайсы проблемалар комплексын үз эченә ала, һәм аларга бертөрле генә җавап та юк. Халыкларның үзбилгеләнү процессы тизләнгәннән-тизләнә бара, һәм халыкара җәмгыятькә яңадан-яңа милләтләр кушыла бара. Аларның әле бик үк утырып җитмәгән мәнфәгатьләре һәм дәгъвалары да бар.

Милләт, дәүләт һәм халыкара җәмгыять — өчесе дә бер-берсе белән үзара бәйләнгән төшенчәләр, һәм аларда дәверебезнең тирән сәяси процессларын күреп була. Бөтен халыкара сәясәт шулар тирәсендә әйләнә, безнең ил тормышы да шулар тирәсендә әйләнә. Халыкара җәмгыятьтә милләтләр үз дәүләтләре төсендә вәкил булып торалар. Халыкара эшләрдә башкача катнашу юк. БМО әгъзасы булмаган халыклар, саннары миллионнар белән исәпләнсә дә, «уен»га катнаша алмыйлар, юл читендә басып калалар. Мәдәниятләре дә планета үсешенең магистраль юлыннан бара алмый.

Дөньядагы дәүләт формалары бу халыклар өчен богауга әверелә, һәм бу нормаль хәл түгел. Бүгенге Русия җитәкчелегенең милләтара мөнәсәбәтләрне акыл белән чишү юллары күренеп тормый. Ул һаман да «бердәм һәм бүленмәс Русия» тезисына ябышып ята. Ә бу бөтен халыклар мәнфәгатенә генә түгел, «демократия» дигән төшенчәнең үзенә дә каршы килә. А.Сахаровның Конституция проекты Русия демократиясе тарафыннан чынлыкта кире кагылды, шуңа күрә Русиядә реформалаштыруның цивилизацияле юлына өмет

итүе кыен. Ул гына да түгел: көрәш коралы итеп А.Солженицын концепциясе алынды. Анда татарлар аңгыра халык мисалында, хәтта украин һәм белоруслар да бөек урыс милләтенең кыйпылчыклары итеп кенә карала. Бер әдәби курьез итеп кенә кабул ителергә тиешле нәрсә Русиядә рәсми идеологиягә әйләнде, җитәкче директива булып чыкты. Димәк ки, кыен сынауларга әзер булырга кирәк. Алда юллар озын әле. Империяләр тыныч кына үлеп китмиләр. Үлеп беткәнче дөньяга шактый сасы таратып яталар.

I БАШЛАМ

## Этнос – халык – милләт: дәүләтчелеккә бару

### *I. Милләтара мөнәсәбәтләрнең чияләнгән төене*

Милләт һәм дәүләт — болар асылда аерылгысыз төшенчәләр. Теләсә нинди дәүләт тә билгеле бер милләт мәнфәгатен гәүдәләндерә. Ул милләтнең теле, мәдәнияте, йолалары монда беренче урында тора. Урындагы түрәләр шушы милләт өчен кадерле булган идеаллар сагында тора. Франция — французлар дәүләте, Төркия — төрекләрнеке, Япония — японнарныкы, Русия — урысларныкы. Урыс хөкүмәте, әйтик, татарлар мәнфәгатен яклау өчен билгеләнеп куела дип уйлау гаять беркатлылык булыр иде. Ул хөкүмәт, башка тирәндәрәк яткан нәрсәләрне әйтеп тә тормастан, татарның хәтта телен генә дә белми ләбаса. Дәүләт милли кадере булган нәрсәләрне үстерү һәм киңәйтү өчен төзелә. Бар халыклар турында да бертигез дәрәҗәдә кайгыртучы дәүләт дөньяга тумаган әле. Бер халык күпсанлы булып, мөстәкыйльлеккә тарихи аклана торган дәгъвалары булганда бу бигрәк тә шулай. Мондый халык хакимлек итүче этносның реаль конкуренты була ала ич.

Милләтара мөнәсәбәтләрдә төп мәсьәлә булып дәүләтчелек мәсьәләсе тора. Соңгы вакытта әдәбиятта халыкларның үз дәүләтләре булмаган хәлдә дә, имештер, гомумдемократик процессларны үстереп, милли-мәдәни автономия һ.б. тудырып үзбилгеләнә алуы турында сафсата шактый еш күренә башлады. Шунысы кызык: шулай дигәндә берәүнең дә бу милли-мәдәни автономия дигәненең ни-нәрсә икәнлеген ачыклап маташканы юк. Тагын да кызыграгы: беркем дә шушыңа ярашлы закон проекты тәкъдим итеп тормады. Башкача әйткәндә, Русиядә бу «үҗәт милләтчеләр»дән, демократлар галәм проблемаларын чишеп чиләнгәндә аларның аяк астында чуалмасыннар өчен, ничек кенә булса да котылырга тырышалар.

Еш кына «милләт» төшенчәсе «этнос» төшенчәсе белән алмаштырыла башлады. Алай иткәндә, бу төшенчәдән дәүләтчелек элементлары төшереп калдырылып халыкларның үзбилгеләнүе ул тел, уку-укыту һәм мәдәният өлкәсендә хокукларны ниндидер бер эфемер сурәттә киңәйтелүе һәм шул рәвешле фикер офыгыннан сәяси процессларның юкка чыгуы булып калыр иде.

Кайберәүләр, бала-чагаланып, имештер, паспортта кайсы милләттән икәнеңне күрсәтмәсәң, милли мәсьәлә хәл ителер иде, дип тәкъдим итәләр. Бу очракта алар Көнбатыш илләрен мисал итеп китерәләр. Анда, чыннан да, кешенең кайсы милләт баласы икәнен язып тормыйлар, чөнки сәбәбе бик гади: фәлән-фәлән дәүләт мәрдәне (гражданы), чыгышы белән кем генә булмасын, шушы дәүләт милләтеннән дип исәпләнелә. Ләкин бездәге кебек үзбилгеләнүнең гадәти геноцидка китерүе бик ихтимал. Үзләренең хокуклары бүгенге көнгә кадәр әле торгызылмаган Кырым татарларына нишләргә калыр иде соң? Идел буе алманнары (немецлары), әгәр дә бөтен кеше дә Русия мәрдәне (гражданы), ягъни «урыс» дип исәпләнсә, үз дәүләтчелекләрен ничек кайтарырлар иде? Аннары паспортка кайсы милләттән икәнеңне язмау белән генә кешеләрнең үзаңнарын үзгәртеп буламы соң әле?! Менә халыкларның үз дәүләтчелекләрен булдырып үзбилгеләнүе тәмамлангач, республикалар тигез хокуклар алып, үз мәрдәнлекләрен (гражданлыкларын) гамәлгә ашыргач, чыннан да, андый язуның хаҗәте калмаячак.

Дәүләт формаларыннан тыш үзбилгеләнү дигән нәрсәне алга сөрү ул Русия империясен демократиясезнисез генә саклап калырга маташудан башка бернәрсә дә түгел. Милли мәсьәләне хәл итү ул — димәк, халыкара җәмгыятькә керергә әзер булган, тарихи процесс субъекты булып җитешкән халыкларның үз дәүләтен яки дәүләтләрен булдыру дигән сүз.

Беренче карашка гади генә булып күренгән халыкларның үзбилгеләнү хокукы, бу хокук субъектын анализлап караганда, шактый катлаулы булып чыга. Берәр территориядә шушы җиргә хуҗа булырга хаклыгы тарихи яктан ачык күренеп торган берәр халык яши икән, монда инде үзбилгеләнүнең бәхәссезлеге дә аермачык: шушы милләт нигезендә милли дәүләт булдырылырга тиеш. Әгәр дә инде ул территориядә берничә милләт, халык яши икән, монда мәсьәлә катлаулана. Бигрәк тә бер милләт халкы төп утырган халык булып, икенчесе басып алу вакытында килеп урнашкан булса, катлаулык арта. Моңа тагын Русия Федерациясендә гадәти хәл булган республикаара чикләрнең милләтләрнең кайда ничек урнашулары белән туры килмәвен дә бергә кушсаң, проблемалар төене шундый каты булып чияләнә ки, аны инде чишеп торасы да килми башлый: кулыңа балта ал да чабып кына ташла...

Бу дәүләтнең җәфаланган нәрсәсе халыкларның берсе эченә берсе кереп урнашуында гына да түгел, ә табигый кыенлыкларга өстәп, ясалма төстә республикалар ясалуында (декретлануында) да. 1920 елда Татар Автоном Совет Социалистик Республикасын булдыру үзбилгеләнү акты булудан бигрәк, киресенчә, шушы акттан котылырга омтылыш иде. 1918 елны Идел-Урал Штаты булдыру турындагы һәм шул ук елгы Татар-Башкорт Республикасы («Кече Башкортстансыз») төзү вариантлары хәзерге чикләрендәге Татарстанга караганда күркәмрәк иде. Хәлбуки большевикларның шундый әһәмиятле аралашу юллары өстендә куәтле дәүләт калкып чыгуыннан котлары алынды. Аннары гади генә Татарстанның Казахстан белән чиктәш булып китүеннән курыктылар. 1920 елгы декрет аңлы рәвештә татарларны зур-зур кисәкләргә бүлде дә аннан соң, ике арага Ырынбур өлкәсен салып, татар, башкорт, казахлар арасында коридор булдырды. (1926 елга кадәр Ырынбур Казахстанның башкаласы иде.) Ләкин хикмәт монда гына да түгел. Хикмәт шунда ки —Татарстан Республикасы чынлыкта бер өлкә генә булып калды, аның бары шул «дәүләт» дигән исеме белән дәүләт тамгалары гына бар иде. Реаль хокуклары юк иде.

1990 елның августында Татарстан ССРның дәүләт суверенитетын игълан итү үзбилгеләнү акты булды. Ул үз алдына реаль дәүләт хокуклары булдыруны максат итеп куйды. Татарстанның суверенитеты, табигый инде, Русия Федерациясендә яшәп килгән структуралар белән каршылыкка килде. Бу каршылык республикабыз язмышы өчен иң әһәмиятле нәрсәгә әйләнде. Әмма шул ук каршылык Русия өчен дә язмыш белән бәйләнгән. «Татарлар мәсьәләсе» күңелсез бер сызлавыктан Русиянең милли-дәүләт корылышының төп проблемасына әверелде. Ул Русия җитәкчелеген милли мөнәсәбәтләр өлкәсендә берсеннән-берсе ашыгычрак адымнар ясарга этәреп тора.

РФ Президентының милли мәсьәләләр буенча киңәшчесе булып торган Г.Старовойтова Татарстанга карата рәсми позицияне күп тапкырлар кабатлап килде. Имештер, Татарстан Республикасының суверенитетын Русия һәм башка республикалар танысын өчен татар халкының күпчелек тәшкил итүе кирәк, ә Татарстанда татарлар 48% кына булгач, Русия эчендә суверен дәүләтнең булуы һич мөмкин түгел. Г.Старовойтованың тел төбендә нәрсә ята иде? Ул Татарстанның суверенитеты республикадагы татар халкының гына мәнфәгатен чагылдыра дип фараз итте. Әмма шунысы бар: Декларация бөтен халыклар исеменнән игълан ителде, татарлар исеменнән генә түгел, һәм ике телне — татар һәм урыс телләрен — дәүләт телләре була дип карар кылды. Декларацияне бөтен депутатларның да (бер битараф депутаттан башка) яклап тавыш биргәнлекләре бик тә җитди сәяси факт булып тора. Татарстан Республикасы Югары Советы карарларының очраклы түгел икәнлекләрен күрсәтүче башка фактлар да бар. Татарстанда Русия Президентын сайлаулар хурлыклы төстә җимерелде, ә Татарстан Президенты өчен татарлар гына түгел, урыслар, чувашлар һ.б. халыклар да үз тавышларын бирде. Шулай булгач, Татарстанда кемнең үзбилгеләнүе хакында,— татарларның гынамы, әллә бөтен халыкныңмы,— сүз куертырга кирәкме? Республика мөстәкыйльлегенең хуҗасы, иясе кем булып чыга соң?

Сәясәтчеләр һәм галимнәр, күрәсең, шуннан чыгып фикер йөртәләрдер: янәсе дә, урысларның үзбилгеләнүе күптәннән булган һәм аларга кабат үзбилгеләнеп торуның кирәге юк. Русиядән читтә, бигрәк тә татарлар белән бергә! Шуңа күрә суверенитет татарларга гына кирәк ул дигән нәрсә килеп чыкты. Әмма бу очракта сәяси вазгыять истә тотылмый: урыслар милләт буларак яши торган дәүләт-империя җимерелде ләбаса. Инде ул дәүләт юкка чыккан икән, аның төп этносы булган урысларга да кабат үзбилгеләнүдән башка юл юк. Бу процесс инде бара һәм шушы хәл урысның язмышына язылган.

Моңарчы урысларның үзбилгеләнү территориясе булып СССР торды, ул ук Русия дә иде, чөнки СССРда дәүләт теле урыс теле иде, Союз органнарында, асылда, урыс кешеләре генә утырды, массакүләм коммуникация чаралары урыс телендә эшләде. Урыс булмаган халыклар вак милләт дип исәпләнде, аларның хокуклары бик нык чикләнгән иде. Һәрхәлдә, Союз республикаларының хокуклары, мәсәлән, Дания кулы астындагы Гренландиянекенә караганда күпкә ким иде. Шушындый хәл булмаган булса, «суверенитетлар парады» да килеп чыкмаган булыр иде. «Зур Русия» хәзер юк инде. «Чит» дәүләтләрдә калган урысларга, мәскәүләрнең ни кылануларына да карамастан, торган урыннарда җай табып яшәргә туры килә. Дөнья бу!

Аңлау һәм аңлатуны таләп итә торган тагын бер кызыклы факт бар — ул РСФСРның үз дәүләте суверенитетын игълан итүе. Һичшиксез, бу урысларның «кече» Русия буларак Русия Федерациясе чикләрендә икенче тапкыр үзбилгеләнергә тырышып караулары иде. Әгәр дә, шактый гына кешеләр расларга маташканча, аларның дәүләтчелеге мең ел буе яшәгән икән, урысларга өр-яңадан үзбилгеләнүнең нигә кирәге булды икән соң? Әйтик, французларның да, японнарның да үз дәүләтләренең суверенитетын яңабаштан игълан итү уе башларына да кереп чыкмый булыр. Бу эшкә тотынсалар, алар көлкегә генә калырлар иде. Ә менә урыслар очрагы беркемгә дә көлке булып тоелмады. Димәк, урыслар нәкъ менә үзбилгеләнү стадиясендә торалар булып чыга. Ләкин үз дәүләтләрен бүген тудырганнары өчен түгел, ә империянең таркалуы аркасында.

РСФСРның үз суверенитетын игълан итүенә җавап рәвешендә Русия автономияләренең «суверенитетлар парады» башланды. Чөнки алар Русиядәге унитар корылыштан туйганнар һәм тарихи процесстан читтә калулары белән моннан ары килешеп яшәргә теләмәделәр. «Кече» Русия аягына торып басарга өлгергәнче таркала да башлады, һәм урыслар тагын үзбилгеләнү проблемасы белән йөзгә-йөз торып калдылар: бу юлы инде әүвәлге автоном республикалар кысаларында.

Русия Федерациясе үзенең милли-дәүләт корылышына тәэсир итә торган ике җитди проблема белән очраша. Аның беренчесе — урыслар белән аралашып, уртак территориядә яшәүче халыкларга карата мөнәсәбәтләрне ачыклау. Икенчесе — «урыс» Русиясен чагыштырмача мөстәкыйль регионнар исәбенә бимәркәзләү (децентрализацияләү). Ерак Көнчыгышның, Сахалинның, Өркет өлкәсе, Ставрополь крае, Петербургның һ.б.ларның үзләренә автоном республика хокуклары таләп итүе бу тенденциянең шактый җитди икәнлеген күрсәтә.

Әйтеп кителгәннәр — урыслар өчен яңа, мәгълүм дәрәҗәдә көтелмәгән проблемалар, һәм мин урысларның «бөтен һәм бүленмәс Русия»не теләсә нинди юллар-ысуллар белән дә саклап калырга әзерлеге хакында бик ашыгып хөкем чыгармас идем. «Меңьеллык Русия» дигән эфемер империяне саклап калу хакына урысларның көч куллана башлаулары икеле. Ул булмаса, нишләп соң алайса Союз таркалды?! «Зур Русия» таркалып, «урыс калалары анасы — Киев» та «чит» илдә булып чыккан икән, татар каласы Казан Русия Федерациясе составында калыр дип кем гарантия бирә алыр?!

Психологик яктан әһәмияте зур булган тагын бер момент игътибарны җәлеп итә. «Урыс телле» булганнары хәлдә дә ни өчен соң ни СССР, ни РСФСР урыс мәдәниятен үстерү турында уйламадылар, ә икътисади вә социаль яктан урысларның хәле «башка» халыклар хәленнән әллә ни аермалы түгел. Шуңа күрә дә аңнарында «бөек патшалык» фикере әле ятса да, урысларны автоном республикаларда алай чит итмиләр. Провинциядәге урыслар үзләрен «милләтчеләр» кебек үк таланган һәм кимсетелгән халык дип сизәләр. Моңа өстәп тагын катнаш гаиләләрне дә искә алып узыйк. Шуңа күрә дә урысларның «тәртибе» Русия сәясәтенә караганда урыннардагы җитәкчелеккә ныграк бәйле.

Урыс милләте ике «милләткә» аерылган булып чыкты: аның берсе — мәркәзнең үз кулында метрополия функциясен тотып торган түрәләр «милләте». Аннан башка Мәскәү якын араларда үз-үзенең дә тамагын туйдыра алмаячак, һәм икенчесе — провинцияләрдәге, башка дөньяда башка уйлар-мәнфәгатьләр белән яшәп ятучы урыс коллары «милләте». Еш кына бу «милләт» милли территорияләрдә кардәшлек белән гомер итеп ята. Бу сәяси факт белән санлашмаучы кеше урыс халкын аңламый да, белми дә дигән сүз, башка нәрсә түгел.

1917 елгы инкыйлабтан соң урыс милләтендә кире кайткысыз үзгәрешләр булды. Совет хөкүмәте урысларның чит илләргә чыгып качкан мөһаҗирләрен дошман күрде. Милли як сыйнфый як белән алыштырылды һәм милли мәнфәгатьләргә төкереп карау совет дәүләтенең кагыйдәсенә әйләнде. Бүгенге көндә дә әүвәлге Союз республикаларында калган урысларга Русиянең мөһаҗирләргә караган кебек каравы һич тә гаҗәпкә калдырмый. Шушы фикер сөреше белән барсак, Русия Федерациясенең үз эчендә дә урыслар мөһаҗирләр хәлендә кебегрәк дип әйтергә тиеш булабыз, һәрхәлдә, Русия җитәкчелеге демократлар артыннан иярмәгәннәргә нәкъ менә шулай карый.

Шулай итеп, ни тышкы, ни эчке сәясәтендә Русия урыс халкының хокукларын яклаучы да, саклаучы да булып тора алмый. Шуңа күрә урысларга терәкне урыннарда, республикаларда өмет итәргә генә кала. Шуннан соң Татарстанны суверенлаштыруда һәм 1992 елның 21 мартындагы референдумда Татарстанның бәйсезлеге өчен күп урысларның тавыш бирүенә ничек гаҗәпләнмәк кирәк?!

Татарстанда дәүләт суверенитеты бар халыклар исеменнән игълан ителде. Ләкин «бар халыклар» нинди берлек соң ул? Төрле этнослар бүген бер дәүләттә яшәп, киләчәктә дә бергә торырга ниятлиләр икән, мөгаен, монда нindидер берлек бардыр, аңар нинди исем бирергә? Суперэтносмы ул, яңа бер милләтме, күпмилләтле халыкмы? Бер-береннән шулкадәр үзгә халык булган татарлар белән урысларның бергә яшәве мөмкинме? Ул бер вакытлы гына хыялый бергәлек булып чыкмасмы? Әллә ул бәхетле киләчәккә йөз тота аламы? Алдагы бүлектә без бу сорауларга җавап табарга тырышып карарбыз.

## *II. Этнос һәм милләт*

Татар, урыс, чуваш, мари һ.б.лар турында сөйләгәндә, без аларны милләтләр дибез. Без, шул ук берлекләрне күз алдында тотып, аларны этнос дибез. Ниһаять, шул ук күренешләргә без халык дибез. Бер үк объектны билгеләгәндә нигә өч төшенчә кулланабыз соң? Берсен генә алырга килешсәк, яхшырак булмас идеме икән? Ә бәлки, без бүгенге терминологиягә хаталы мәгънә салабыздыр.

Этнос — биосоциаль күренеш ул. Ул табигатьне җәмгыять белән бергә кушып карый. Этнос биологик җегәргә ия була һәм социаль процесслардан битәр башка кануннарга буйсына. Күп вакытта «үзеңнең ата-бабаңны оныт син, без бөтенебез бер халык балалары» дигән сүзләрне дә ишетәсең. Бу фикерләр әлеге күренешнең асылына төшенмәгәннән генә килә. Этнос буенча аермалык ул кемдер теләге белән түгел, ә табигать биргән бер Алла тамгасы белән аерымланудыр. Кеше дигән адәм баласына өйрәтә-өйрәтә башка бер этнос төсләрен иңдереп булса да, аның үз канында булганын чыгарып ташлавы мөмкин түгел.

Этносларның табигый холкы милләтара низаглар вакытында бик ачык күренә башлый. Тиешле чагында туктатып кала алынмаганда, алар кешеләр арасында турыдан-туры сугыш китереп чыгаралар һәм, икътисади, сәяси, хокукый һәм башка чараларны санга сугып тормыйча, үзләренең биологик бакчасына килеп керәләр. Күреп торабыз бит, мондый низаглар озакка сузылып китә; мәгънәсе дә бетә, әмма алар барыбер бара, чөнки аларны бетерерлек процедура юк. Шунда инде көч куллану мәсьәләсе алга килеп баса.

Элеккеге совет әдәбиятыннан безнең көннәргә чаклы милләт белән этносны сәер генә бутап йөртү ияреп килде. Шул ук вакытта иҗтимагый процессларны юньләп аңлата алмаса да, һаман да милләт турында Сталинның сүзләре кулланыла. Турыдан-туры да, күчереп тә йә булмаса башка кием кидереп тә кулланалар. Хәтта үзләрен сталинизмның кан дошманнары дип атаучылар да фикерләү инерциясенә биреләләр.

Этносның яшәве өчен Сталин аңлатуындагы берлек — «тел, территория, мәдәният, икътисад һәм халык берлеге» им түгел. Татарлар, гаять киң территорияләргә утырып, төрле республикалар, төрле илләрдә яшиләр. Мәсәлән, Польшадагы татарлар татар телен һәм мәдәниятен инде онытканнар, ләкин мөселман динен, исемнәребезне, халкыбыз тамгаларын саклап киләләр һәм, татар этносының төп өлешеннән гасырлар буе аерым яшәүләренә дә карамастан, үзләрен татарларның аерылгысыз бер өлеше дип исәплиләр. Бер үк вакытта алар поляк милләтенең дә бер өлеше, алай гына да түгел, шул милләтнең бик тә мөхтәрәм өлеше булып саналалар. Чөнки алар һәрвакыт тугрылык белән король гвардиясендә, ә соңрак Польша армиясендә хезмәт итеп килгәннәр.

Этнос берлеге булсын өчен уртак дин тоту да им түгел. Керәшен татарлары, православие динендә булулары аркасында, татарның төп массасыннан шактый үзгәрәк, әмма барыбер алар татар этносының бер өлеше.

*III. Этнос берлеге булсын өчен кайвакыт үзаң булу да җитә*

Сталинның «милләт» төшенчәсен аңлатырга да хәленнән килми, чөнки анда милләтнең төп сыйфаты — дәүләтчелек төшереп калдырылган. Кешеләрнең нинди дә булса берлеген милләткә әверелдерүче төп сыйфат ул — дәүләт. Берәр дәүләттә уртак мәнфәгатьләр белән яшәп ятучы мәрдәннәр (гражданнар) милләт хасил итәләр дә инде. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: нәкъ менә шуның өчен Көнбатышта паспортка «милләт» тамгасы сугылмый. Кайсы этностан чыгышларына карап тормастан, бөтен мәрдәннәр дә шушы милләт вәкилләре дип саналалар. Әйтик, Франциянең теләсә кайсы мәрдәне — тумышы белән французмы ул, немецмы, алжирлымы, төрекме — барыбер француз дип исәпләнелә. Әйтелгәннәрдән бу ике төшенчә арасындагы аерманы чамаларга мөмкин. Этнос булсын өчен үзаңның булуы да җитә икән. Ә милләт оешу өчен исә дәүләтчелек булу зарур. Милләт ул — уртак мәнфәгатьләр белән бер дәүләттә яшәүче кешеләр берлеген чагылдыручы социаль организм.

Бер караганда, этнос тулысы белән милләткә әверелеп китәргә мөмкин кебек. Ләкин моның гамәлгә ашуы бик икеле: этнослар утырган җирләр чиге белән дәүләт чикләрен тәңгәл китерүе бик кыен нәрсә: бөтен дөньяда этнослар башка халыклар белән бер-бер артлы булып утырганнар, ә бу дәүләтнең максатларына һәм хәтта хосусиятенә дә төзәтмәләр кертә.

Этнос белән милләтнең бер-берсеннән килеп чыкканлыгы аермачык, һәм бу бик зур роль уйный. Милләт һәм аның тиешле дәүләте билгеле бер этник культура нигезендә генә туа ала. Чөнки дәүләт идарә итә алырлык, уку-язуны, фәнне һ.б. үстерергә сәләтле кешеләр катлавы булуны таләп итә.

Югары үсешкә ирешкән этнос — милләт һәм дәүләт калкып чыксын өчен мәҗбүри шарт. Шул ук вакытта социаль тормышта төрле этнослар бер-берсе белән даими рәвештә бәйләнештә торалар, һәм милләт, кагыйдә буларак, этник чыгышлары төрле-төрле булган мәрдәннәрдән җыела, ләкин боларның уртак максатлары, нормалары һәм кыйммәтләре булып алар үз ихтыярлары белән шушы дәүләт тарафыннан урнаштырылган тәртипләргә буйсынырга әзер торырга тиешләр. Кыскача әйткәндә, милләт ул — этник чыгышларының нинди булуына карамастан бергә береккән мәрдәннәр берлеге.

Дәүләт бөтен мәрдәннәрне бербөтен итеп тота ала торган мәгълүм бер мәдәни даирә булганда гына яши ала. Берлек бетсә, дәүләт тә бетә. Әлбәттә, тарихта бер-берсенә каршы булып бер милләткә укмаша алмаган этносларны үз эченә алган империяләр булганлыгы билгеле нәрсә. Көчләп тупланган мондый конгло-

мератлар була ала, ләкин аларның гомере этнослар гомере белән чагыштырганда (Л.Гумилевча — 1200 ләп ел) бик кыска була. Хәтта империяләр дә, бер идеология яки дингә, ассимиляция һ.б. таянып, нindидер ялган берлек булдырырга омтылалар. Ләкин эчке бәйләнешләр булмаганда, бер генә дәүләт тә озак яши алмый.

Милләт бер генә этностан торырга да, полиэтник булырга да мөмкин. Мәсәлән, Япониядә япон булмаган кешеләр бик аз (бары 1 процент). Әле шунда да төп тамыр дип бөтенесе 20 мең кеше булган айналар исәпләнә. Мөгаен, шуңа күрә Япония милли омтылышлар бик ачык чагыла торган дәүләт булып торадыр да. Бу идеологиядә, мәдәнияттә һәм сәяси кыйммәтләрдә генә түгел, бөтен нәрсәдә дә — хәтта экономикада да (мәсәлән, сәүдә мөнәсәбәтләрендәге протекционизм), салымнар системасында, идарә итүдә, фирма эчендәге мөнәсәбәтләрдә дә күренә. Мондый монолит милләтнең мәдәниятне артык унификацияләү кебек үз кимчелеге дә бар, ә бу хәл җәмгыятьнең иҗади җегәрен киметергә мөмкин. Японнар, җитәрлек төрлелек булдыру өчен аерым провинцияләрдә мәдәниятне үстерүне стимуллаштырып, әлеге кимчелектән котылырга тырышалар.

Нинди дә булса берәр мәдәниятнең ачыктан-ачык өстенлек иткәне хәлендә бик тә төрле этнослардан торган милләтләр дә була. Американнар шундыйлардан. АКШ — мөһаҗирләр (эмигрантлар) иле. Монда төрле-төрле этник төркемнәр инглиз телле даирәдә, тегермәндә тартылгандай, бөртек урынына тартылалар. АКШта этник проблемалар глобаль характерда түгел. Алар, асылда, индеецларга, алеутларга, пуэрториканнар, мексиканнарга гына кагыла. Боларның башкалардан аерым үз менталитетлары бар. Ләкин бу әле инглиз телле даирәдә ирландлар, итальяннар, кытайлар һ.б. бөтенләй эреп юкка чыга дигән сүз түгел. Беренче буын мөһаҗирләр чыннан да мондагы социаль нормаларга яраклашырга, үз тамырларын искә төшермәскә тырыша. Болар үз ватаннарын ташлап китәргә мәҗбүр булган кешеләр, күкрәкләрендә еш кына аңа карата үпкә хисләре тулган була, шуңа күрә бөтен өметләрен алар яңа ватаннарына баглыйлар. Икенче буындагылар инде «йөз процент американ» булып күренергә тырыша, һәм бары социаль статус ныгып җиткәч, өченче-дүртенче буыннарда гына этник хисләр уяна башлап, кешеләр үзләренең чыгышларын искә төшерәләр, бабалары телен өйрәнә башлыйлар, аларның ватанына кайтып, каберләрен эзлиләр, алар гомумамерикан даирәсендә нинди дә булса хосусият белән аерылып торырга тели башлыйлар. Этник тамырларга кайту үзүзеңне танытуның бер формасына әверелә.

АКШны этносара җитди проблемалардан монда халыкларның дисперслы урнашуы да коткарып килә. Әгәр дә нинди дә булса бер территориядә бер этнос вәкилләре генә күпчелек алып торган булса, илдә Канаданың француз телле Квебек шәһәрендәге кебек проблемалар килеп чыкмый калмас иде, шаять. Мәгълүм дәрәҗәдә АКШта этник проблемаларны салым салу системасы да йомшарта. Ул монда астан өскә таба юнәлтелгән, ә бу хөкүмәткә күп кенә проблемаларны, хәл ителәсе мәсьәләләрне җәмәгать яки муниципаль дәрәҗәгә төшерергә ярдәм итә. АКШ — мул тормышлы, чәчәк атучы ил. Әгәр дә анда икътисад аска тәгәрәсә яки сәяси кризис башланса, этносара каршылыкларның ничегрәк күренәсен әйтүе кыен. Тормыш бозыла калганда, этник казанның Америкада да кайный башлавы бик ихтимал.

Өстенлек итүче бер мәдәнияте булган, ләкин үз эченә югары үсешкә ирешкән, үзбилгеләнүне таләп итүче этносларны алган милләтләр дә була. Моңа мисал итеп Квебек проблемасы булган һәм Атлантика провинцияләре АКШ ягына омтыла торган Канаданы, Басклар Иле һәм Каталониясе булган Испанияне, Төньяк Ирландия, Шотландия һәм Уэльсларның сепаратизмы булган Бөекбританияне алырга мөмкин. Шотландия мисалы һәрьяктан да гыйбрәтле, чөнки Бөекбритания — хокукый дәүләт өлгесе, анда кеше хокуклары саклана һәм этносара конфликтлар монда күренмәскә тиеш иде кебек. Хәлбуки эш башкачарак тора — шотландлар үзләренең автономиясе белән килешмиләр, аларның мөстәкыйль милләт буласылары килә. Бөекбритания федеральләшү проблемасы алдында тора. Үз вакытында валлон һәм фламанд этнослары басымы белән Бельгия дә федеральләшүгә барырга мәҗбүр булган иде.

Безнең өчен аерым кызыгы булган тагын бер төр милләт була. Ул дәүләт хасил итә торган тигез хокуклы берничә этностан тора. Моңа мисал итеп Швейцарияне алырга була. Анда тигез хокуклы дүрт этнос бар, немецча сөйләшүче швейцарлар сан ягыннан күбрәк булсалар да, хакимлек итүче мәдәният һәм тел монда юк. Швейцариядә полиэтник милләт кенә түгел, полиэтник федератив дәүләт тә. Шуның белән АКШ һәм Германиядән аерылып та тора. Ләкин бу хакта сүз алдарак булыр.

*IV. Милли азчылыклар, төп халыклар һәм мигрантлар*

Милләт хасил иткәч, этнослар юкка чыкмыйлар, яши бирәләр, әмма хәзер инде аларны дәүләтләре яклый. Аларның теле, мәдәнияте, гадәтләре, йолалары рәсми статус ала, аларның максатлары һәм дәгъвалары

дәүләтнекенә әверелә. Дәүләт хасил итүче була алмаган этнослар белән эш башкачарак тора, аларның хәле, сәяси ситуациягә карап, төрлечә тулы хокуксызлыктан алып автономия статусына кадәр булырга мөмкин.

Моноэтник (бер генә этностан торган) дәүләт ул — иллюзия, гамәлдә җир йөзендә андый дәүләтнең булганы юк. Теләсә нинди дәүләттә төрле-төрле этник төркемнәр яши. Аларның хокуклары яклауга мохтаҗ була. «Саф милли дәүләт» идеясе үзе үк еш кына башка халыкларның ихтыяҗларын күрергә комачаулый. Хәлбуки ул ихтыяҗлар һәрвакыт була һәм алар тора-бара сәяси факторга әвереләләр.

Милли азчылыклар (нацменьшинства) ул — дәүләт хасил итүче этнос эчендә яшәүче этник төркемнәр. Алар үзләренең этник билгеләрен һәм үзләренә генә хас ихтыяҗларын саклыйлар. Безнең китапларда еш кына социаль хокуклар белән милли хокуклар буташтырып йөртелә. Мондый буташтыруның авторлары, кагыйдә буларак, әлеге хокуклары инде бар халык вәкилләре булып чыга. Социаль мәгънәдәге тигезлек хакимлек итүче башка тел һәм мәдәният уртасында яшәүче милли азчылыкларның этник үсешен тәэмин итә алмый. Әгәр милли азчылыкларга аерым хокуклар тәэмин итмәсәң, аларны дискриминациядән аралау мөмкин булмый, алар ассимиляция, йотылу куркынычы алдында кала. Андый хокукларга туган телне куллану, үз мәктәпләрен булдыру, мәгариф һәм мәдәният органнары оештыру, милли азчылыкларның хокукларын яклау һәм саклау өчен сәяси һәм башка җәмәгать оешмалары булдыру хокукларын кертергә кирәк. Күп илләрдә милли азчылыклар өчен парламентта урыннар гарантияләнә, хөкүмәт постларында квоталар бар, ә кайчакта «автономия» статусы да кертелә. Милли азчылыкларның хокукларын яклауга мисал итеп Финляндиядәге шведларның хәлен алырга мөмкин. Алар монда 300 мең чамасы (барлык халыкның 8 проценты). Аларның теле монда дәүләт теле һәм ул этник шведларга гына түгел, финнар өчен дә мәҗбүри өйрәтелә. Аларның күпләбрәк яши торган урыннарында ул әле рәсми тел дә булып тора. Этник шведларның үз газеталары, партияләре, университетлары, махсус радио һәм телевизион каналлары бар. Моңа, кагыйдә буларак бигрәк, аннан чыгарма дип карарга да ярый. Гадәттә, милли азчылык теле дәүләт теле булып тормый, ә аларның хокуклары белем бирүнең автоном системасы һәм мәдәни ихтыяҗларны үтәү белән чикләнә. Ләкин Финляндиядә шведларның хәле бик тә гыйбрәтле хәл, ул милли азчылыклар проблемасын хәл итүнең принципиаль юлларын күрсәтә.

Кайбер чит илләрдә үз дәүләтләре булган милли азчылык белән үз дәүләтләре булмаганнары хәле арасында зур аерма бар. Беренче очракта проблема шушы дәүләттә инде әзер продукцияне тарату юлы белән мәдәниятне киңәйтү, уку-укыту системасын, матбугатны җайга салуга кайтып кала.

Икенче очракта без бөтенләй башка ситуациягә тап булабыз. Монда мәдәниятне үстерергә кирәк, ә бу дәүләт ярдәменнән башка мөмкин эш түгел. Этнос үз билгеләрен үз дәүләте булмаса да саклап кала ала, әмма заман таләпләре дәрәҗәсендә алга бару әле үз дәүләтең булганда да бик катлаулы нәрсә, ә ул булмаганда бөтенләй дә мөмкин түгел. Каты итеп әйткәндә, бу очракта безнең алда милли азчылыкларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү проблемасы булудан бигрәк этносның үзбилгеләнүе яки деколонизациясе проблемасы тора. Моның классик мисалы булып АКШта индеецларның хәле тора. Ә ул, әйтик, Германиядәге төрекләр яки Франциядәге алжирлар хәленнән тамырдан аерыла. Индеецлар, аларның территориясен басып алган американнардан аермалы буларак, үзләренең тарихи ватаннары җирендә яшиләр һәм Американың төп, тамыр халкы булып торалар. Явыз империя булган АКШ белән өзлексез көрәштә аларның берничә буыны туып үсте. Индеецлар американнарның кануннарын, гадәт-йолаларын һәм әхлакларын һич үзләренеке итә алмадылар. Бүген АКШ, аларга резервацияләр булдырып һәм аларның мәдәниятен үстерүгә акчалар тотып, үз гөнаһларын юмакчы була. Ләкин борынгы этносның тамырына балта чабылган шул инде.

Төп, тамыр халыклар проблемасы — глобаль проблема ул. Чөнки дөнья этносларыннан бик азы гына үз дәүләтләрен булдыра алганнар. Мөгаен, бу проблема Русиядәгегә караганда башка бер җирдә дә шулкадәр үткенлеге белән тормый торгандыр. Монда йөздән артык төп, тамыр халыклар яши, аларның хокуклары танылмаган һәм кануннамә белән тәэмин ителмәгән. Русия репрессияләнгән халыкларның хокуклары торгызылмаган Аурупадагы бердәнбер дәүләт булып калды.

Төп, тамыр халык булып шушы территориядә җитешкән һәм үзенең этник сыйфатларын, билгеләрен саклап калган этнос санала. Нигез сыйфат итеп төп, тамыр халыклар буенча БМО нотыкчысы бу халыкның кем тарафыннан булса да басып алынган булуын китерде. Шулай булганда, урыслар Русиянең зуррак өлешендә төп, тамыр халык булып чыкмыйлар.

Төп халыкның күкрәгендә һәрвакыт үз хәленнән канәгатьсезлек хисе дөрли, аның тарихи хәтере әүвәлге бәйсез яшәгән көннәренә әйләнеп кайта. Шунда аның мөстәкыйль үсешкә, үз җиренә, тереклек итәргә кирәкле ресурсларына үзе хуҗа булу дәгъвасы калка. Туган телен үстереп, аны административ һәм хөкем органнарында, мәдәни һәм башка максатларда куллану теләге көчәйгәннән-көчәя бара. Төп халыкның икътисади, социаль һәм теләсә нинди башка проблемалары этник төс ала. Дөнья тәҗрибәсе моның бетмәслеген күрсәтә һәм шуңа күрә аны факт буларак кабул итәргә кирәк тә.

Төп халык проблемаларын гамәлдә, аның санына, ничек урнашуына карап, икътисади һәм сәяси вазгыятьтән чыгып, төрле юллар белән хәл итәргә була. Шундый юлларның берсе — кануннар нигезендә төрле ташламалар, дәүләт дотацияләре һ.б. бирү. Икенче юл — автономия бирү. Бу очракта автономия үз эченә, БМО нотыкчысы тәкъдим иткән «Төп, тамыр халыклар хокукларының Бөтендөнья декларациясе проекты»на туры китереп, түбәндәге функцияләрне ала: белем бирү, информация, мәдәният, дин, сәламәтлек саклау, торак мәсьәләләре, социаль иминлек, борынгыдан килгән һәм башка төрле икътисади хезмәт төрләре, җирдән файдалану һәм ресурслар белән идарә итү, әйләнә-тирәне саклау, шулай ук шушы автоном функцияләрне финанслау максаты белән эчке салым салу. Мөмкин булган хокуклардан тышкы сәясәт, оборона һәм валюта (акча) мөстәкыйльлеге монда керми. Мондый автономия чынлыкта Гренландия эскимосларында бар. Саннары 32 мең генә булса да, аларның үзләренең кануннар чыгаручы органы һәм ике дәүләт теле — дат һәм эскимос теле бар.

Русиядәге хәлне бөтен дөньяда кабул ителгән нормалар белән чагыштырып карасаң, Русия җитәкчелегенең кешенең элементар хокукларын аңламавына, үҗәтләнә-үҗәтләнә империя басып алуларын сакларга тырышуына исең китә. БМО рекомендацияләрен гамәлгә ашырса, Русия җитәкчелеге, хәтта халыклар үзбилгеләнмәгәндә дә, әле илдә хәлне тотрыклы итә, хакимият структураларын чын-чынлап реформалый алган булыр иде. Бүген исә төп халыкларга бер генә юл кала — үз бәйсезлекләре өчен сәяси һәм икътисади чаралар белән көрәшү генә.

Хәлнең фаҗигасе шунда күренә ки, Русия халыклары хәтта үз исемнәре белән аталган республикаларда да милли азчылык хокукларына ия түгел. Мари Эл, Чувашия һәм Удмуртия республикаларында милли хәрәкәтләр еш кына мари, чуваш, удмуртларның хокуклары өчен үз хөкүмәтләре белән көрәшергә мәҗбүрләр. Бу республикаларның хөкүмәтләре үз халыклары мәнфәгатен кайгыртучы булу урынына «мәркәз» сәясәтен үткәрүчеләр булып чыктылар. Русиядә бер яктан колониаль сәясәт, икенче яктан тәлинкә тотып тору үзенә күрә бер яхшылык дәрәҗәсенә куелган.

Төп халыкларның үзбилгеләнүе — мәсьәләне хәл итүнең иң радикаль юлларыннан берсе. Хәлбуки бу очракта проблема яшәп яткан дәүләт кысаларында халыкның автоном хокукларын гади генә киңәйтүгә караганда тамырдан үзгә булып чыга. Дәүләтчелеккә әйләнгәч, автономия сәяси нисбәтләрен үзгәртеп кенә калмый, ә моңарчы колак ишетмәгән яңа сәяси төшенчәләр дә китереп кертә. Мөстәкыйль, бәйсез дәүләтнең мантыйгы (логикасы) автономиянеке белән чагыштырганда бөтенләй башка. Автономия мантыйгы — этник мантыйк: милли азчылык булган бер халыкны яклау вә саклау. Бәйсез дәүләт мантыйгы — милли мантыйк: бу дәүләтне хасил иткән барлык этнослар һәм мәрдәннәрне яклау вә саклау.

Үзбилгеләнү барышында «төп, тамыр халык» төшенчәсе үзенең әүвәлге сәяси мәгънәсен җуя. Яңа гына оешып килә торган дәүләткә бу процесс инициаторы булган төп халык белән генә түгел, шушы ук рольне дәгъвалаучы барлык этнослар белән дә санлашырга туры килә. Аннан соң, үзбилгеләнә торган этнос бу өермәгә үз территориясендә яши торган башка халыкларны да өстери, башка берлеккә әверелә: халыкка әйләнә, ә аннары бүгенге кыйммәтләре күп яктан әүвәлгеләренә туры килеп торган милләт булып үсеп җитә. Нәкъ менә шушындый хәл Татарстанга хас. Монда төп, тамыр халык этник төшенчә булып сәяси роль уйнамый. Татарстанның бәйсез дәүләт булып үзбилгеләнүен тәэмин итүдә төп халык булган татарларга өстенлек бирү түгел, ә урысларга да татарлар хокукын булдыру уңыш китерер. Татарстанда татарлар һәм урыслар дәүләт хасил итүче этнослыкны дәгъва кылуларын ачык белдерделәр. Шул ук вакытта Татарстан монда тыгыз укмашып яши торган этносларның, аларның саннары күп булуга карап кына түгел (мәсәлән, чувашлар 137 мең), ә аларның милли республикалары белән чиктәш булганлыгы аркасында да, ул этносларның мәнфәгатьләрен истә тотмый кала алмый.

Җәмгыятьтә аерым бер категория кешеләр бар, алар — мигрантлар. Аларның проблемалары милли азчылыкныкыннан аерыла. Чөнки алар бу дәүләт мәрдәннәре түгел, бу җирдә утырып калырга ният итмиләр дә. Мигрантлар этник түгел, ә социаль күренеш. Дорфарак итеп әйткәндә, ул — эшче куллар. Аларны язмыш җилләре бу милли даирәгә китереп ташлаган, ләкин алар үз мәнфәгатьләре белән яшиләр. Аларның үз психологиясе, үз ихтыяҗлары була һәм алар төп этнослар белән генә түгел, теле, мәдәнияте һәм этник чыгышлары үзләрен берләштерә торган милли азчылыкларга карата да аерым бер мөнәсәбәттә торалар. Балтыйк буенда бу проблема бик ачык күренде. Анда урыслар ике төркемгә бүленде: берсе хәзерге хәлгә ияләшергә, мәдәни даирәне кабул итәргә, үзенең этник кыйммәтләрен саклап калырга, икенче төрле әйткәндә, үзен милли азчылык кебек тотарга тырышса, икенче төркем шул дәүләт кануннары белән яшәргә җыенмый һәм шуңа күрә сәяси көрәшне яки ул дәүләттән китеп баруны артыграк күрә.

Моңа охшашлы хәлне төрле вариацияләрдә теләсә кайсы республикада очратасың. Татарстанда мигрантлар психологиясе бигрәк тә Чаллы шәһәре мисалында ачык чагыла. Бирегә үз заманында әйбәт акча эшләргә дип шактый күп очраклы кешеләр килеп төште. Аларны үзләренең кем балалары булулары, этник чыгышлары да кызыксындырмый, ә инде республиканың тарихы һәм мәдәнияте турында әйтеп тә торасы

юк. Моңарчы Чаллыда саф карамаклык (ведомоство) фикере яшәп килде. Бер буклетка, мәсәлән, «Набережные Челны — город КамАЗа» дип язылган иде. Бу карамаклык милкенә әйләнгән мигрант психологиясенең үзенә күрә бер триумфы иде. Хәлбуки Чаллының гына түгел, Татарстанның башка шәһәрләре кешеләренең дә психологиясендә үзгәрешләр барганлыгы күз алдында. Ватанпәрвәрлек хисләре үскәннән-үсә бара. 1992 елның 21 мартындагы референдумда Чаллыда республиканың статусын күтәрү өчен сайлаучыларның 60,8 проценты тавыш бирде — бу Казандагыга караганда күпкә артык.

Русиядә этносара мөнәсәбәтләр гаять тә күптөрле. Балтыйк буенда моноэтник дәүләтләр кору юлыннан киткән булсалар, — бу бөтен Аурупада дип әйтерлек шулай, — Русия өчен бу юл мөмкин түгел. Русиягә дини фактор куәтле булган Урта Азия республикалары юлы да килешми. Хөкүмәт православие динен дәүләт дине дәрәҗәсенә күтәрергә күпме генә тырышмасын, теократик (дини) дәүләт өчен социаль база юк. Өстәвенә Русия этник һәм дини яктан бик чуар. Бер генә диннең берләштерү ролен уйный алуы мөмкин түгел. Русиядә үзбилгеләнү республикалар һәм өлкәләрнең бүгенге чикләрендә барачак, ә үзбилгеләнүнең объектлары булып төп, тамыр халыклар гына түгел, урыслар да торачак.

Үзбилгеләнү кешеләрнең үз дәүләтләрен булдырырга дип үз теләк-ихтыярларын ачык белдерүдән башлана. Ул теләк ихтыяр мөстәкыйль сәяси аңда, үзбилгеләнү өчен көрәшүче сәяси фиркаләр һәм оешмалар, дәүләт белән идарә итәрлек кадрлар һәм структуралар булганда күренә. Андый берлек бер яки берничә этностан торырга, бөтен этносны яисә аның бер өлешен үз эченә алырга мөмкин, ләкин ул үзен тарих субъекты итеп тоярга һәм аның үзе дәгъва итә торган, үзе яши торган конкрет территориясе булырга тиеш.

«Халык» төшенчәсе күпкырлы һәм ул күп мәгънәләрдә йөри: 1) җәмгыятьнең җитәкчеләр тарафыннан идарә ителә торган өлеше аны «гади халык» дип йөртәләр. Болар гадәттәге сайлаучылар; 2) мәрдәннәр җәмгыятенең синонимы — республиканың барлык мәрдәннәрен күз алдында тотып, без Татарстан Республикасы халкы дибез; 3) этнос синонимы — җиде миллионлы этносны күз алдында тотып, без татар халкы дибез.

Безгә бу очракта әлеге төшенчәнең ике аспектын күрсәтеп үтү мөһим. Беренчедән, элек тә үз дәүләтләре булган этнослар бар. Аларны милләт дип әйтеп булмый, чөнки милләтләр чагыштырмача күптән түгел формалашканнар, һәм аларның элгәре булмаган бик ачык үз шәкелләре була. Чыннан да, хәзерге милләтләр, борынгы халыклардан аермалы буларак, дөнья сәясәтендәге вазифалары белән үзара бәйләнгәннәр, алар халыкара җәмәгатьчелекнең, икътисадның состав өлеше булып торалар, һәм алар арасындагы мөнәсәбәт халыкара хак-хокуклар белән тәртипкә салына. Бу хәл моннан 200 — 300 ел элегрәк юк иде әле. Тарихи күренешләргә хәзергечә аңлауны китереп тыкмау өчен андый берлекләрне, этнос һәм милләттән аермалы буларак, халык дип атауның үз мәгънәсе бар.

Икенчедән, үз дәүләтен торгызырга яки үзбилгеләнергә омтылучы берлекне «халык» дигән аерым термин белән атауның әһәмияте зур. Андый берлекнең бергә укмашып яши торган мәгълүм дәрәҗәдә чикләре булган территориясе була, һәм ул, полиэтник булып, шунысы белән этностан аерылып та тора. Бу мәгънәдә халык милләткә әйләнү юлында бер күчеш рәвеше була. Бу инде үз хокукларын автономия кысаларында киңәйтергә хыялланучы этнос кына түгел, ул инде дәүләтчелек дәгъвалый, ләкин аның әле дәүләт мәнфәгатьләреннән килеп чыга торган кыйммәтләрнең яңа системасы тумаган була.

Милләт халыктан дәүләт үзбилгеләнүенең тәгәлләнүе белән дә, дөньядагы милләтләр арасында үз урынын алуы белән дә аерылып тора.

Татарстанга кире әйләнеп карасак, без республикада бүгенге көндә татарлар, урыслар, чувашлар һ.б.лардан торган, гомуми территориядә бергә яшәргә риза булган, дәүләт, икътисад, мәдәният белән мөстәкыйль идарә итү өчен сәяси хокуклар алырга омтылган халык хасил булыр дип раслый алабыз.

Башка илләр тарафыннан танылган, үз мәрдәнлеге, үзенең тышкы сәясәте булган Татарстанның бәйсез дәүләт статусын республика халкы — Татарстан Республикасы милләте тәэмин итә.

Шуның белән этносның милли азчылык хәленнән халык, милләт һәм яңа дәүләт булып формалашуы тәгәлләнә, ләкин аның белән әле милли проблемалар тәгәлләнми.

II БАШЛАМ

## Милли азатлык һәм демократия

### *I. Милләтнең азатлыкка таба хәрәкәте буларак демократия*

Милләт — кешеләрнең табигый берлеге, һәм ул шәхесләрнең иҗади эшләвен таләп итә. Төркемнәр, сыйныфлар, катламнар чиге белән бикләп тормыйча, ул кешене, вак иминлектән югары күтәреп, тарихи,

дөньяви, мәңгелек нәрсәләр турында уйланырга мәҗбүр итә. Мәдәнияттән, җәмгыятьтән читтә торган, язмышка буйсынган һәм төзү урынына җимерергә генә булдыра торган коллар милләтсез була.

Милли хокуклары булмаган халык өчен демократиянең бер мәгънәсе дә калмый. Шуңа күрә һәр халык өчен ул үзбилгеләнүдән башлана.

Халыкларның үзбилгеләнүе дәүләт корылышының приори рәвешләрен күз алдында тотмый. Бертөрле халыклар үз дәүләтләрен булдырып, башкалары мескен бичаралар хәлендә яшәргә тиеш дигән принципның дөньяда булганы юк. Теләсә нинди халыкның тарихта үз кадере бар, шуңа күрә, урыскамы анда, инглизчангамы өстенлек биреп, чеченны яки шотландны кысарга беркемнең дә хакы юк. Үзбилгеләнүнең субъекты буларак халык үзе генә торып баса ала, һәм ул үзе генә үз үсешенең рәвешен сайлап алырга хокуклы.

Милли мәсьәлә ул тактика мәсьәләсе түгел, ә принцип мәсьәләсе, һәм шуңа күрә аның өлешләп-өлешләп, этаплап-этаплап хәл итеп булмасына минем иманым камил, һәм ул хәл ителгәндә йә тулы күләмдә һәм беркемне дә аермыйча бөтенесе өчен дә хәл ителә, йә ил гел-гел милләтара тетрәнүләр эчендә яшәргә дучар булып кала.

Империя структураларыннан иртәрәк котылып, төрле хәлләр аркасында бәйсезлекне башкалардан иртәрәк алуга ирешкән халыклар да була. 1917 елдан соң Финляндия белән Польшада шулай булды, безнең чорда элеккеге Союз республикалары белән шул хәл кабатланды. Ләкин системада калганнар бер җепкә бәйләнгән булып чыга. Империянең асылы шунда: ул бөтенесен дә иң изелгән халык дәрәҗәсенә куярга омтыла. Бу канунның үзгәрәсе юк. Монда чик буенда урнашу да, этник составның нинди булуы да, халык саны да, нинди дә булса башка берәр фактор да коткарып кала алмый. Украина 1917 елдан соң күпсанлы халкы һәм гаять зур экономик потенциалы булган, уңайлы геополитик хәлле нигездә бәйсез дәүләт булды. Ләкин берни дә коткармады, 70 ел буена украиннар СССРдагы башка теләсә нинди милләт хәленә төшерелде. Милли мәсьәлә хәл ителмәгән яисә өлешчә генә хәл ителгән системада бар халыклар да иртәме-соңмы барыбер хокуксызлыкта тигезләнәләр.

СССРда милли мәсьәлә һәрвакыт хәрби мәсьәләнең бер өлеше булып килде. Бу аңлашыла да. Соң, Казан ханлыгыннан башлап бөтен яңа территорияләр дә басып алынды лабаса һәм корал көче белән тотып торылды. «Ирекле» кушылулар ул — соңрак уйлап чыгарылган идеологик кармак кына. Әүвәлрәк андый түбәнлеккә төшеп тормаганнар, халыкларны яулап алу зур дәрәҗә дип исәпләнгән һәм теләсә нинди сәясәтне дә шуның белән аклаганнар. Шул хәл Русия халыкларында «меңьеллык» патшалыкка каршы потенциаль куркыныч күрә торган фикерләүне китереп тудырган. Илнең дәүләт эшлеклеләренең күпчелеге милләтара проблемаларга сәясәтчеләргә караганда хәрбиләрчә якын киләләр, ягъни низаглар инде килеп чыккач кына исләренә киләләр дә шундук коралга ябышалар. Алар халыкларның тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынып азапланмыйлар, иң әйбәт дигәндә дә, бу мәсьәләне бик тә тенденциоз яктырткан дәреслекләрдән алган мәгълүматлар белән канәгатьләнәләр. Татарлар турында нәрсәләр генә язып бетермәгәннәр дә, ул ялганнар кайларга гына барып җитмәгән. Шуннан соң дөньяда татарларны ни рәвешле күз алдына китерүләренә гаҗәпләнеп торасы калмый.

Русия җитәкчелеге үзенең халыкларга карата хәрби сәясәтен псевдодемократиянең идеологик пәрдәсе белән капларга тырыша. Демократия үзеннән-үзе милли мәсьәләләрне хәл итәчәк дигән әкият таратыла. Әгәр ул шулай була торган булса, Төньяк Ирландиядә, Басклар Илендә сугыш булмас иде, чәчәк атучы Квебек аерылырга омтылмас иде, Бельгия федерациягә күчеп маташмас иде, ә АКШтагы индеецлар турында без Фенимор Купер китапларын укып кына белгән булыр идек. «Бик күпләр идеаль өлге дип санаучы Америка демократиясе ни өчен индеецларны канәгатьләндерми?» дигән гади генә сорау куеп карыйк ди. Ни өчен иң демократик булган илләрдә дә халыклар үзбилгеләнү өчен көрәшәләр? Бар халыкларга да ярый торган үрнәк демократия буламы, әллә инде һәрбер халык демократиянең үзенә генә яраклы рәвешен сайлап аламы?

Абсолют һәммәсен дә канәгатьләндерә торган демократия булмый. Демократик режимны конкрет милли мәнфәгатьләрне истә тота торган дәүләт урнаштыра. Башка халыклар хокуклары бу очракта аңа читләтеп кенә кагыла. Билгеле, тоталитар режимнан аермалы буларак, демократик режим этник төркемнәргә үз мәдәниятләрен сакларга рөхсәт итә, демократик илләрдә этник чыгышың өчен эзәрлекләү юк, анда Кырым татарлары, Идел буе алманнары (немецлары) яисә ингерманланд финнары проблемалары була алмый. Хәлбуки кешенең яки этник төркемнең яшәргә булган хокукы белән халыкның лаеклы үсешкә хокукы арасында зур аерма бар.

Икенче бер әкият тә бар әле. Анысы, имештер, базар мөнәсәбәтләренә күчкәч, милли проблемалар үзләреннән-үзләре хәл ителә дип расламакчы. Алай гына да түгел, күп кенә сәясәт әһелләре демократияне, базар мөнәсәбәтләрен һәм милли проблемаларны хәл итүне бер-берсе белән тәңгәл күрәләр. Мондый караш чынбарлыктан ерак тора. Базар мөнәсәбәтләре бик иркенләп диктатура белән килешеп яши ала, алай гына да түгел, еш кына базар мөнәсәбәтләренә күчеш үзе диктатура булуны таләп итә башлый. Ә милли пробле-

маларга килгәндә, базар аларны катлауландырып та җибәрергә мөмкин. Инде бүген үк хосусыйлаштыру милли төсмер ала башлады. Халыклар, аеруча аз санлы халыклар җиргә, хосусый милек кертүгә борчылып торалар, чөнки җир йөзендәге соңгы терәкләреннән колак кагулары бар. Күп кенә регионнарда төп халыкларның предприятиеләрдә эшчеләрнең түбән квалификацияле өлешен алып торганнары сер түгел, һәм, болай булгач, эшсезлек аларга беренче булып килеп кагылачак. Төрле республикаларның кузгалып китү мөмкинлекләре бертөсле түгел. Берәүләрнең икътисади структуралары базарга якынрак торса, икенчеләрнең ераграк тора; берәүләрнең чимал ресурслары җитәрлек, икенчеләрнең бөтенләй юк. Кыскача әйткәндә, базар мөнәсәбәтләре милли тормышны җиңеләйтү урынына катлауландырачак кына.

Дөнья гамәле күрсәткәнчә, демократиянең югары дәрәҗәсе дә, икътисади бөтенлек тә үзләреннән-үзләре генә милли мәсьәләне хәл итми.

Хокукый дәүләт бишеге булган Бөекбританиядә Ольстер бар, югары үсешкә ирешкән Канадада — Квебек. Милли мәсьәлә аерым, мөстәкыйль мәсьәлә генә түгел, ә даими игътибар таләп итә торган гаять катлаулы мәсьәлә дә. Аның үзенчәлеге шунда: үз вакытында хәл ителмәсә, ул хокук нормалары һәм актларына бирешми башлый, физик катнашу, фәкыйрьлек һәм хокуксызлык хасил итеп, җәмгыять тормышын параличлый. Метастаза сыман, ул бөтен иҗтимагый организмны агулый. Регионнарның милли үзенчәлекләре ул җәмгыятьнең экзотик бизәге генә түгел, дәүләт организмындагы ялтыравык яисә бигрәк тә төрле хәрәкәтләр һәм «фронтлар»ның бәйләнчеклеге түгел, ә дәүләтнең асылы, аның яшәвенең максаты һәм мәгънәсе ул.

Милли азатлык белән демократия арасында антагонизм килеп чыгуын кем генә теләр икән. Ләкин, ни аяныч, тормыш дигән нәрсә кайчак, миннән дә, синнән дә сорап тормыйча, бу мәсьәләне алга китереп ярып сала; сала да еш кына шуларның икесенең берсен сайлап алырга мәҗбүр итә.

Дөньяда демократиядән дә кадерлерәк берәр нәрсә бармы икән? Безнең заманда бу сорауның үзенең үк хәерсез булып күренүе мөмкин. Хәлбуки Каталониядә, Көрдестанда яисә Татарстанда үзбилгеләнү хакына көрәшүчеләр өчен моның җавабы көн кебек ачык — алар, ике дә уйлап тормастан, бөтен кадерле нәрсәләр арасыннан милли азатлыкны сайлап алачаклар, һәм милләтчеләрнең моңа дәлилләре җитәрлек булачак. Әйтик, татар халкы өчен аның азатлыгын кем бууының ни аермасы бар: патша режимымы ул, милләтләрне кушу буенча коммунистик сәясәтме яки иске тәртипле, яңа лозунглы псевдодемократик Русияме, — барыбер түгелмени?! Милләтчеләр демократиянең халыкларга азатлык китерә торган кадәресенә өлгәшү өчен көрәш алып баралар.

Милли азатлыкның үз кадере бар. Демократияне халыкларның үзбилгеләнүенә каршы куярга азаплану ул демократия өчен көрәш дигән күркәм сылтау белән азатлыкка каршы юнәлтелгән сәяси уеннан башка бернәрсә дә түгел. Милли азатлык булганда, дәүләт корылышы демократик яисә авторитар булырга мөмкин, ләкин инде азатлык юк икән, демократия гомумән дә була алмый. Күп сәясәтчеләр милли азатлыкка омтылышны сепаратизм һәм экстремизм күренеше дип атыйлар, шул ук вакытта халык тарих субъекты булганда гына демократия була алганлыгы кебек гади хакыйкатьне башларына да кертеп чыгармыйлар. Демократия ул — халык хакимияте, ләкин ирексез халык тарихи процесстан читкә алып ташланган була. Милли азатлык ул — демократиянең тәүге тибеше дә, аның нигезе дә. Гомумән, демократия яки милләтнең суверенитетына бәйләп карамый торган «саф» демократия — алдау ул. Урыс дөньясында, милли үзбилгеләнү проблемасы булмагач, төп мәсьәлә булып идеология килеп баса, ягъни кайсысын сайларга: коммунизмнымы, әллә антикоммунизмнымы, капитализмнымы, әллә социализмнымы? Урыс булмаган халыклар өчен беренчел мәсьәлә булып азатлык мәсьәләсе тора, чөнки, тарих күрсәткәнчә, алар аны капиталистик Русиядә дә, социалистик Русиядә дә татымадылар. Ләкин бит ахыр чиктә урыслар да, башка халыклар да бер җеп белән бәйләнгәннәр. Әгәр урыс демократиясе башкалар өчен ирексезлек булып калса, ул чакта ул кешенең этник чыгышы белән санлашып тормый торган яңа төр диктатурага әвереләчәк. Шуның өчен дә шул Русиянең демократлашу мөмкинлеге үзе үк милли-дәүләтчел үзгәртеп корулар белән бәйләнгән.

Яшәп тора торган дәүләт һәрвакыт халыкның үзбилгеләнүе юлында киртә була, чөнки теләсә кайсы дәүләт тә үзенең status-quoсын һәм территориаль бөтенлеген сакларга омтыла. Русиянең Англиядән йә булмаса башка берәр демократик илдән аермасы шунда: Аурупа илләрендә милли азчылыкларның мәгълүм дәрәҗәдә азатлыгына ирешелгән, һәм аларның ул азатлыкны киңәйтергә омтылышлары табигый күренеш дип кабул ителә. Ә Русиядә үзбилгеләнү теләген генә дә дәүләт җинаяте сыман кабул итәләр. Чын-чыннан демократик дәүләт тоталитар дәүләттән шунысы белән аерыла да инде — ул халыкларның үзләре теләгән рәвештә үзбилгеләнүенә каршы килми, ә шуңа ярдәм итә.

Русиядә демократия дип, кагыйдә буларак, күпчелекнең фикерен ачыклый торган тавыш бирү процедурасын аңлыйлар. Урыслар 82 процент тәшкил иткәч, Русиядә милли проблемалар, гомумән, булырга тиеш түгел дип карыйлар, чөнки һәр очракта да күпчелек урыслар ягында булачак. Бу — демократиянең механик күпчелек «хокук»ына нигезләнгән примитив рәвеше генә. Ул башка халыкларның хокуклары булырга

тиешлеген танып маташмый, ул милли яисә социаль азчылыклар хокукларын һәм шәхес хокукларын бар дип тә белми. Ул мәнфәгатьләр балансын яки аларны килештерүне белми, аңа «консенсус» төшенчәсе ят була. Ә халыклар үз мәнфәгатьләрен кайгырта башласа, бу рәвешле демократия тормыш белән каршылыкка керә һәм гаҗизлектән, күпчелек ихтыярын үтәү аргументы буларак, көч кулланырга өнди башлый.

Демократия бары тик милли хокуклар контекстында гына эчтәлекле мәгънә ала. Социаль, милли максатлардан аерым торган «саф» демократиянең мәгънәсе бетә, ул тавышларны механик җыюга әйләнеп кала. Тарихи яктан демократик принциплар милли казанышлар буларак салынып киләләр. Либерализм идеяләре француз мәгърифәтчеләре тарафыннан эшләнә, гамәлдәге хокукый дәүләт Бөекбританиядә туа, хәзерге демократик нормаларның күбесен алман социал демократлары бәян итә, федератив принциплар АКШта урнаша, референдумнар дөньяга Швейцария җирлегеннән тарала. Демократик принципларның үз конкрет милли чыганаклары һәм үз ияләре була. Алай гына да түгел, дәүләт корылышының бер рәвеше буларак, демократия милләт үсешенең табигый бер этабы да булып тора.

Демократия — чиксез кадерле нәрсә, ләкин ул Аурупадагы империяләр таркалгач кына хасил була. Халыкларның үзләренә ярашлы демократия рәвешенә баруларының тарихи бер логикасы бар. Демократияне халыктан көч белән тартып алып була, ләкин аны көч белән тагып булмый. Көчләп тагып урнаштырылган демократия гадәти диктатура булып чыга.

*II. Кеше хокуклары контекстында милли хокуклар*

Иң изге идеяләр дә былчыратылган Русиядә милли хокуклар бозылып кабул ителә, өркү һәм хәтта нәфрәт тә уята. Халыкларның тигез хокуклылыгына еш кына оятсыз тәкәбберлек дип, ә суверенитетка дәүләт җинаяте сыман итеп карыйлар. Башы чуалган Русия җитәкчелеге катлауланып киткән этник проблемалардан, кеше хокукларын яклау лозунгысы артына качып, котылып калырга азаплана.

Кешедәге кешелекне миллилектән аерып карап булмый. Индивид — тарихи традицияләр иясе, ул тел һәм гыйлем җыю аркасында шәхескә әйләнә. Шуңа күрә кеше хокукларына иң элек туган телеңдә сөйләшү хокукы, үз мәдәниятеңне үстерү, яшәрлек мөмкинлекләрнең булуы һәм башка хокуклар керә. Шушы иң гади, иң табигый хокуклар булмаганда, башкаларының кирәге дә шулкадәр генә кала. Үз халыкларына балаларын камил милли мәктәпләрдә укытырга мөмкинлек тудырмый торган, халыкларның мәдәниятләрен саклау һәм үстерү өчен җитәрлек матди мөмкинлекләр бүлеп бирми торган хөкүмәтләр теләсә нинди нәгърәләргә дә лаеклы.

Русиядә төп, тамыр халыклардан шүрләү кеше хокукларының, имештер, беренчел, ә халыклар хокукларының, янәсе, икенчел булуы турында әллә нинди ялган теорияләр уйлап чыгарырга мәҗбүрләр. Бу мәсьәләнең бөтен нечкәлекләрен аңлау өчен «милләтче» белән «демократ» диалогын «тыңлап» карыйк әле.

«Демократ». Кеше хокукларыннан өстен бернәрсә дә булуы мөмкин түгел. Бу кешелек дөньясының иң зур казанышы, XX гасыр гуманизмының квинтэссенциясе, кеше хокукларының беренчеллеген танымау ул — җәмгыять үсешенең цивилизацияле үсеш юлын кире кагу.

«Милләтче». Мин кеше хокукларын танырга әзермен, ләкин халыклар хокуклары белән бергә.

«Демократ». Кеше эшчәнлеген милләт белән бәйләп карау ул — әүвәлге кеше ихтыярын коллективка буйсындыруның тоталитар практикасын дәвам итү дигән сүз. Кеше азатлыгы — беренчел. Калган барысы шуңа өстәлә генә.

«Милләтче». Сорау бирергә рөхсәт итегез. Кеше хокуклары, аның азатлыгы теләсә кемгә дә кагыламы, әллә сайлап алынганнарга гынамы?

«Демократ». Әлбәттә, бөтен халыклар да тигез хокуклы. Бу — безнең иманыбыз, kredoбыз, ягъни һәр кеше дә, милләтенә, диненә, социаль чыгышына, җенесенә, тән төсенә карамастан, тигез хокукларга ия.

«Милләтче». Тигез хокуклылыкны туган телеңдә сөйләшергә, тиешле белем алырга, күмәк информация чараларына бертигез мөмкинлекләр булу дип акларга ярыймы?

«Демократ». Һичшиксез!

«Милләтче». Алайса, минем менә телевизордан фильмнарны туган телемдә карыйсым килә, балаларымны бакчада көчли-көчли башка телдә сөйләштермәсеннәр иде. Мин кеше хокукларын шулайрак аңлыйм.

«Демократ». Бу проблемалар турында минем дә ишеткәнем бар һәм монда бер яңалык та тапмыйм. Шунысын гына әйтәсем килә: бөек принципларны андый ваклыклар белән бутамыйсы иде. Иң әһәмиятлесе — кеше хокукларын чикли торган тоталитар дәүләтне җимерергә кирәк.

«Милләтче». Әмма минем бөтен гомерем шул ваклыклар белән үтте. Милли белем алып булмаган, казна эше минем туган телдә бармый торган дәүләттән миңа ни файда? Бәлкем, минем таләпләремнең нигезе юктыр?

«Демократ». Юк, нишләп булмасын, бик нигезле. Ләкин сез, милләтчеләр, үзегезнең шул бәләкәй генә милли дөньягызга бикләнеп яшисез. Мәктәпләр өчен дә, башкасы өчен дә конкрет кешеләр җаваплы. Әнә шулардан таләп итәргә кирәк тә. Без кора торган демократик дәүләттә бөтен бу мәсьәләләр автомат рәвештә, үзеннән-үзе хәл кылыначак. Сабыр итәргә генә кирәк.

«Милләтче». Соң, мин бит инде 1552 елдан бирле «сабыр итәм». Әллә ул гомер генә җитмиме әле?

«Демократ». 1552 елның ни катнашы бар монда? Моңарчы әле чын демократиянең булганы булмады. Менә, ниһаять, без хәзер цивилизацияле мөнәсәбәтләр дәверенә керәбез. Бүген иң әһәмиятлесе — уртак тырышлык белән демократиянең җиңүенә ирешәсе иде, ә калганы шуңа ялгана аның. Сез, милләтчеләр, азатлыктан да кадерле нәрсә юклыгын аңларга тиешсез.

«Милләтче». Минем өчен дә милли азатлыктан кадерлерәк бернәрсә дә юк, демократия ул — шул милли азатлык бит инде. Башка тагын берәр төрле азатлык бармы әллә?

«Демократ». Сез азатлыкны бик примитив аңлыйсыз. Миллилек ул — үзенә күрә тоталитаризм, ул шәхес азатлыгын чикли.

«Милләтче». Минем халкымны коллар хәленә төшергән дәүләт — тоталитар дәүләт, һәм, димәк, тоталитаризм да милли азатлык булгач кына бетәчәк.

«Демократ». Тоталитаризмны бетергәч, һәркем өчен азатлык булачак.

«Милләтче». Ә демократик дәүләттә милли хокуклар саклануына нинди гарантия бар?

«Демократ». Демократик дәүләттә кайсы милләттән булуның әһәмияте булмый.

Бу әңгәмәне тагын да дәвам итеп булыр иде. Ләкин теләсә кайсы очракта да проблема әнә шул халыклар хокукларының гарантына барып төртеләчәк. Халыклар хокуклары гарантияләнмәгәндә, кеше хокукларының бәясе — сукыр бер тиен. Андый гарантияне дәүләт бирергә дә мөмкиндер. Ләкин менә нинди дәүләт бит ул? «Демократ»ларның җавабы әзер: демократик дәүләт. «Милләтче»ләр өчен демократия проблемасы төп мәсьәләне чишкәннән соң — үз дәүләтләрен булдырганнан соң гына килеп туа. Шуңа чаклы «демократик дәүләт» алар өчен, иң яхшы дигәндә дә, ул мәгълүм сәяси йомшартулар булуны, начар дигәндә, изү субъектын алмаштыруны аңлата.

Русиянең урыс булмаган халыкларның хокукларын якламаячагы көн кебек ачык. Инде әгәр дә мәгәр Русия Бөекбритания кебегрәк демократик дәүләт булып китә икән, анда да аның үз «Ирландия»се яки «Шотландия»се булмас дип ышанып әйтүе кыен. Ә инде Русия Америка юлын сайласа (ә ул хакта аның җитәкчеләре кабат-кабат белдерделәр), ул чакта андагы халыкларга Америка индеецларының хәле үзләренә җәннәт булып күренердәй мескеннәр язмышы әзер булачак.

Русия дәүләтен тамырдан үзгәртеп кормыйча торып, милли мәсьәләне принципта хәл итеп буласы юк. Халыкларның хокукларын яклау һәм саклауны, шушы мәнфәгатьләр сагында торырдай тиешле дәүләт структуралары булмаганда, бернинди демократия дә тәэмин итә алмаячак.

Проблема шундадыр ки: этник чыгышыңнан принципта беркая да качып котыла алмыйсың, «саф» кеше хокуклары дөньясында гына калып булмый. Халыкара документларда кеше хокукларының халыклар хокуклары белән бербөтен итеп каралуы юкка гына түгел ул. «Кеше хокуклары хартиясе» өч документны берләштерә. Алар: Кеше хокукларының Бөтендөнья декларациясе, Мәрдәни һәм сәяси хокуклар турында пакт, Икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклар турында пакт. Әгәр дә беренче документ шәхес хокукларын ачыкласа, калган икесе халык хокукларына карый. Әлеге пактларның 1 нче маддәсендә болай дип язылган: «1. Бөтен халыклар да үзбилгеләнүгә хокуклы. Шул хокукка нигезләнеп, алар үзләренең сәяси статусларын үз ирекләре белән урнаштыралар һәм ирекле төстә үзләренең икътисади, социаль һәм мәдәни үсешләрен тәэмин итәләр.

2. Бөтен халыклар да үз максатларына ирешү өчен, халыкара икътисади хезмәттәшлектән, уртак файдага нигезләнгән һәм халыкара хокуктан килеп чыга торган нинди дә булса мәҗбүриятләргә зыян китермәслек итеп, үзләренең табигый байлыкларыннан һәм ресурсларыннан үзләре теләгәнчә файдалана алалар. Бер генә халык та һичбер нинди очракта да үзенең яшәве өчен кирәкле һәм үзенеке булган мал-мөлкәтеннән көчләп баш тарттырыла алмый.

3. Ошбу Пактта катнашучы дәүләтләр, шул исәптән үзидарәсе булмаган һәм аның карамагына кергән территорияләр өчен җаваплылык тота торганнары да, Берләшкән Милләтләр Оешмасы Уставы кагыйдәләре нигезендә үзбилгеләнү хокукын тормышка ашыруны хупларга һәм ул хокукны хөрмәт итәргә тиеш».

Халыкларны яклау зарурлыгын истә тотып, БМО 1948 елны үзенең Уставында, ә аннары 1966 елны әлеге пактларда халыкларның үзбилгеләнү хокукын кеше хокукларының иң төпкеләреннән берсе сыйфатында игълан итте. Бу принцип нигезендә теләсә нинди халыкның үз җиренең һәм үз язмышының хуҗасы булырга, туган телен һәм мәдәниятен якларга һәм сакларга, үз милли дәүләтен булдырырга хокукы бар. Өстәвенә андый хокукка иң элек төп, тамыр халык (санына да карамыйча) ия. Бары былчыранып беткән иҗтимагый фикер генә үзенең тарихи ватанында үз дәүләтен булдыру өчен төп халык күпчелекне тәшкил

итәргә тиеш дигән теориягә барып җитәргә мөмкин. Бер генә халыкара документта да, халык язмышы турында сүз барганда, демографик чикләүләр күрсәтелмәгән.

Халыклар хокуклары контекстыннан тыш кеше хокукларының мәгънәсе калмый, чөнки кеше хокукларын бозмауның гаранты төсендә дәүләт була. Әлбәттә, хыялда этник билгеләре булмаган барлык дәүләтләр өчен дә уртак булган хокук нормалары тупламасын күз алдына китерергә мөмкин. Теориядә бу операцияне эшләве кыен түгел, ә тормышта кеше үзенә бер аерым конкрет телдә сөйләшә, ул конкрет бер мәдәният иясе һәм моннан йөз чөерү мөмкин булмый. Асылда, мәсьәлә кеше хокукларын тану яки танымауда түгел, мәсьәлә бу хокукларны бозмауны, өстәвенә тулы күләмендә, бернинди кыскартуларсыз саклауны ничек тәэмин итүгә кайтып кала.

Кешеләргә үз гадәт-йолалары, мәдәниятләре кадерле, һәм башкалар күзендә бу кыйммәтләр яхшымы-начармы — кешеләр аларның дәүләт тарафыннан яклануын һәм саклануын телиләр. Аларны булганынча кабул итәргә кирәк, бернинди «демократик» стандартлар кысаларына тыгызлауның һич тә кирәге юк. Мәдәни кыйммәтләрне яхшы-начарга, өстен-түбәнгә, алдынгы-артта калганнарга аера башладың исә, колониализмга, империализмга һәм тоталитаризмга туп-туры юл ачылачагын көт тә тор. Аларны ничек бар, шулай кабул итәргә кирәк тә.

Әйтеп үтелгәнчә, халык хокуклары контекстында карала торган кеше хокукларының гаранты булып милли дәүләт калка. Хәлбуки тормышта этник һәм дәүләт чикләре бер-берсенә туры килеп бетмиләр, һәм шуның өчен проблема тагын да катлаулана төшә. Алай гына да түгел әле, полиэтник структуралы халык булганда нәкъ менә моноэтник дәүләт тигез хокуксызлык чыганагы булырга мөмкин. Русиянең төп проблемасы шунда: эчтәлеге белән полиэтник булуына да карамастан, хокукый яктан ул бары урыс дәүләте булып кына чыга. Олуг патшачыл (великодержавный), православный һәм бүленмәс Русия күптөрле халыкларның хокуклары гаранты була алмый. Ә Федератив Русия хәзергә ирешүе кыен булган максат кына булып кала.

Тышкы «богау»лардан арыну ул — әле азатлыкның беренче баскычы гына, һәр милләтнең әле шәхес иреген чикли торган эчке «богау»лары да була. Халык азатлыгының эчке ягын да күрмәү ялгышлык булыр иде. Милли дәүләт үзенең яшәве өчен генә яшәми, ул кеше азатлыгын үстерү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш, шул чакта мәдәниятнең бөтен потенциаль мөмкинлекләре ачылып, ул дөнья халыклары ярышында уңышлы катнаша алачак. Чын-чыннан ирекле җәмгыять милли демократия үсешеннән башка, мәрдәннәрнең азатлыгыннан, кеше хокукларын тәэмин итүдән башка мөмкин түгел.

### *III. Курку, нәфрәт һәм демократия*

Империянең мәҗбүри атрибутларыннан берсе булып курку-куркыту тора. Репрессия органнары тарафыннан ул хис аерым-аерым һәрбер кешедә генә түгел, тулы-тулы халыкларда да урнаштырыла. Асылда, теләсә нинди дәүләт тә физик көчләүгә корыла, бу нәрсә аның, социаль институт буларак, хас билгесе булып тора. Хәлбуки нормаль хәлендә чакта ил белән идарә итү өчен икътисади, сәяси, юридик, идеологик һәм башка чаралар да артыгы белән җитеп һәм бары тик кризислы әхвәлдә генә яки хокук тәртибен бозучы аерым мәрдәннәргә карата гына дәүләт көчләү юлына баса. Империядә исә барысы да башкача: анда репрессия ысуллары гадәти гамәл сыйфатында файдаланыла.

Империя теләсә нинди ирекле фикерне, рәсмилектән теләсә нинди аерымлыкны эзәрлекли тора. Монда аның идеологиясендә миллилек милләтчелек белән тәңгәлләштерелә, ә «милләтчелек» дигәне кануннан тыш дип игълан ителә. Шулай итеп, мәрдәннәр һәм халыклар күңеленә курку һәм үшәнлек кертелә. Шушы ике нәрсә халыкларны изүне тәэмин итә торган ике коралга әйләнә. Торгынлык елларында татар мәктәпләрен, газеталарын һ.б. ябуда гаепне үз өсләренә генә алып бетермәүләре белән урыслар бик хаклы. Чынлап та, «өстән» бернинди күрсәтмә килүнең дә кирәге калмаган иде. Мәскәүгә татарның үз куллары белән мәктәпләр, газеталар, нәшриятлар ябылсын өчен әлеге куркуны дөрләтеп торуы да җитә иде. Хәтта бүген дә әле Татарстанда күпләр үзләрен бик сак тоталар һәм суверенлык мөмкинлекләреннән файдаланырга бик ашкынып тормыйлар, һәм тиешле вәкарь белән: «Язмыш (тормыш) — куласа: әйләнә дә бер баса»,— дип куялар. Дүрт гасыр да, җитмеш елга сузылган курку-куркыту режимы да үз эшен эшләми калмаган шул.

Гадел булыйк, урыс халкы да куркудан хали түгел. Ул да шулай ук колларча баш иеп яшәде. Шуның өчен, күрәсең, урысларның империяне саклап калырга дигән әзерлеге какшаган булып чыкты.

Куркуның икенче ягында куркытып яшәткән өчен үч алу теләге ята. Тышкы зынҗырларыннан котылган социаль яки этник энергия — коммунистлармы ул, демократлармы, урысларммы яки милләтчеләрме — барыбер теләсә кемгә каршы юнәлергә мөмкин. Мондый хәятта Русиянең үз традицияләре дә шактый гына дәрәҗәдә этәргеч булып тора ала.

Русиядә бер чиктән икенче читкә тайпылу һаман-һаман кабатланып килде. Иҗтимагый аңда дөнья икегә генә бүленә — яхшылык бар да, яманлык кына бар, имеш; оҗмах бар да тәмуг кына бар. Большевиклар бу традицияләрдән файдаланып калдылар. Алар монда исемнәрне генә алыштырып куйдылар. Оҗмах урынына коммунизм дип куелды, тәмуг урынына — капитализм. Классиклар — пәйгамбәр, буржуйлар иблис булып чыкты. Киләчәк дигән сүз белән бөтен аң томаланды. Көн күрү дигән нәрсәнең мәгънәсе дә югалды. Шуңа күрә кешеләр үзләрен дә, башкаларын да кызганып тормый башладылар. Дихотомлы аң, «дошманнарга» карата нәфрәт кузгатып, шул нигездә «революцион борылыш» ясарга юл куйды.

Русиядәге бүген бара торган сәяси көрәш тә шул дихотомлы аңнан ары китә алмый, киресенчә, һәр ике як (коммунистлары да, демократлары да), асылда, нәфрәт хисе белән сугарылган. Русия демократларының необольшевизмы шунда: алар полюсларны алыштырып куйдылар — капиталистлар урынына дошман итеп коммунистларны китереп чыгардылар, социализм урынына Көнбатыш капитализмын куйдылар. Революция логикасы тагын җегәр җыеп килә. Телевидение белән матбугат иҗтимагый аңны мәкерле дошман өрәге белән интектерә, национал-социализм белән, «номенклатура» инкыйлаблары булуы бар һ.б. дип өркетә. Үтелгән 70 ел гомер — «кара еллар» дип, ә революциягә чаклы еллар «бәхетле еллар» дип кенә сурәтләнә.

Большевиклар, социалистик бәхет вәгъдә итеп, хакимият башында утырып тора алдылар, демократлар коммунистлар, башына җитеп һәм капитализмга кире кайтып, бәхеткә килүне вәгъдә итәләр. «Тагы да бераз көч куеп,— диләр алар,— дошманны бәреп бетерәсе дә, аннары бөтенесе дә шәп булыр», янәсе.

Язмышның мыскыллап елмаю шундадыр ки, демократия кешенең богауларын чишә дә аны эчке курку хисеннән арындыра, социаль энергиягә үзен күрсәтергә ирек бирә, һәм нәтиҗәдә үзәкләштерелгән дәүләткә оппозиция килеп чыга. Монда төп көч булып гасырлар буе үз сәгате сукканны көтеп халык йөрәгендә яшәгән этник энергия калка. Тарих күрсәткәнчә, хәтта бәләкәй генә этник төркемнәр дә, әгәр дә хакимият этносларның табигый әхвәлләре белән исәпләшми башлый икән, зур-зур дәүләтләрне дә тетрәтүләре ихтимал. Русия демократлары да большевиклар алдына килеп баскан дилеммага тап булдылар: демократияне йә, ул бөтенләй буйсынмас була башлаганчы, бөтереп кире тыгып куярга һәм репрессия органнарын торгызырга, йә инде туп-туры Русияне таркатып ташлау юлына басарга. Тегесен дә, бусын да гафу итмәячәкләр. Ни гаҗәп: курку хисе демократларның да үз тотышларын билгели. Әгәр дә А.Собчак Татарстанның суверенитет игълан итүе уңае белән биргән интервьюсында: «Большевиклар биргән Русиядән чыгу хокукын бетерергә һәм Русия Федерациясен дезинтеграцияләргә маташуларны кануни көч ярдәмендә туктатып, бу гамәлләрне дәүләт җинаяте итеп саналырга тиешле»,— дип бәяли икән, бу инде, димәк, аның эчендә большевик утыра дигән сүз. Ул, куркуыннан шашып, «милли мәсьәлә»не хәл итүнең бердәнбер юлы шул дип, тизрәк ишек артына сөяп куйган күсәгенә ташланмакчы. Бу без алда әйтеп үткән «Русиядә милли мәсьәлә һәрчак хәрби мәсьәләнең бер өлеше булып килде» дигән тезисны тагын бер тапкыр раслый.

Тарих җәмгыятьнең революцион үсеше белән таныш. Ул «үсеш» нәфрәт белән үч алуга корылган була. Тарих шулай ук үзара сабырлык һәм консолидациягә корылган эволюция мантыйгын да белә. Моның беренчесе башкару өчен гадирәк, ул иҗтимагый аңның гади штампларын кулланып та гамәлгә ашырыла ала һәм нәтиҗәсен дә тиз бирә. Икенчесе исә башкару өчен катлаулы, чөнки аң белән иҗтиһад итүне, төрлетөрле фикерләрне үзара килештерүне, төрле мәнфәгатьләрне һәм җәмәгать көчләрен ризалаштыруны таләп итә. Сәясәттә текәлек һәрвакыт примитив була һәм аның таянычы да эмоция генә була. Центризм һәм эволюционлык аң, сабырлык һәм түземлек сорый.

Большевиклар, халыкларның революцион энергиясен капитализмга каршы юнәлтеп, аны бик тә нәтиҗәле файдаландылар. Бүген исә «антисоциалистик революция»не үткәрү күпкә кыенрак. Вазгыять тамырыннан үзгәрде. Таланган халыкка 1917 елда «буржуйлардан» тартып алыр нәрсә бар иде. Демократлар исә капитализмны халык исәбенә төземәкче: ә бу бер дә рухны күтәрми. Октябрьдә илдә сугыш бара һәм җимереклек хөкем сөрә иде, ә революция юл күрсәтте. Демократлар киресенчә иттеләр — болай имин генә яшәп яткан илне җимереклек һәм сугыш хәленә төшерделәр. Социализм җир йөзендә тигезлеккә һәм гаделлеккә өндәде, һәм бу массаларның киң катламын җәлеп итми калмады. Демократлар социаль аерымлыклар тәкъдим итәләр һәм иң югары максат сыйфатында Көнбатышка табынуны, башкача әйткәндә, бөек дәүләтне Көнбатышның койрыгына әйләндерүне тәкъдим итәләр. Әле шуның белән бергә гап-гади теләнчелектән дә тартынып тормыйлар. Мондый сәясәт массаларны рухландыра алмый.

Сугыша-сугыша төзелгән социализм империалистик системаны какшатты, демократик лозунгларны күркәмләтте, һәм ул, безнең илгә уңай нәтиҗәләр китермәсә дә, калган дөньяны тетрәнергә, эчке көчләрен җыярга һәм, асылда, буржуаз корылышны үзгәртергә мәҗбүр итте. Диктаторлык режимнары алып ташланды, икътисад нәтиҗәле итеп көйләнде, колониаль сәясәттән баш тарттылар. Ә иң әһәмиятлесе — җәмгыятьтә сыйнфый нәфрәт һәм үзара кырылыштан котылдылар. Октябрь дөньяны гаделрәк итеп үзгәртергә тәэсир итте, һәм бу аның тарихи казанышы булып тора.

Бүген инде 20—30 нчы еллардагы кебек, халык массаларының нәфрәтен һәм энтузиазмын кузгатуы кыен. Коммунистлардан һәм милләтчеләрдән «халык дошманы» ясавы авыр. Чөнки, беренчедән, тегеләре дә, болары да бик күп, икенчедән, демократлар үзләре дә шул ук номенклатура карынынннан килеп чыкканнар, өченчедән, төбәкләрдә җитәкче урыннарда шул ук коммунистлар утырып калды һәм аларның антикоммунистик сәясәт алып барасы килеп тормый. Яңа революция булмаячак.

КПСС белән Союз мәркәзен таркаткач, демократларның көрәшер нәрсәсе калмады һәм бу хәл аларның үз сәясәтләрен үткәрү юлында җитди киртәгә әверелде. Шуңа күрә демократлар кабызып җибәрергә тырышкан нәфрәт аларның үз башларына гына төшәчәк.

Русия демократлары коммунистларга каршы «интернациональ» фронт тудыра алмадылар. Әле, киресенчә, милли хәрәкәтләр йөзендә Русия демократлары үзләре дә сизмәстән хуплау түгел, ә оппозиция алдылар. Милли аңның хосусиятен бөтенләй аңламауны Мәскәүнең Чечняга карата алып барган сәясәте ачык күрсәтә. Чечено-Ингушетиядә коммунистик режимны бәреп төшерүдә файдаланылган көчләр Русиягә мөнәсәбәттә коммунистларга караганда да битарафсызрак булып чыктылар, һәм мәркәзнең һәр басымлы адымы саен җавап реакциясе көчлерәк була барды, бу Русиягә каршы тору теләген көчәйтте генә.

Русия халыкларында эчке аерымлану урысларда булганга караганда азрак һәм шунлыктан аларда сыйнфый көрәш ихтималы да кимрәк. Милли азатлык булмас борын алар өчен тышкы каршылыклар эчкеләренә караганда әһәмиятле булып торачак. Шуңа күрә милләтчеләрнең хисләре дә башкарак юнәлештә. Бүгенге көндә күп кенә этник регионнарда нәфрәт объекты булып коммунистлар түгел, ә урыслар тора. Начар тормышка зарланганда, милләтчеләр Мәскәү ягына күрсәтәләр. Аларның нәфрәте үзенә бертөрле, чөнки гомумсоциаль мотивлардан тыш анда үз этник мотивлар да, күп очракта гасырлар буе җыелып килгән үпкә һәм мыскыллар да килеп кушыла. Аяныч хәл, ләкин бу шулай. Нинди генә сурәткә керсә дә, нәфрәт булып кала инде ул. Революцион нәфрәтме ул, демократик нәфрәтме, гаделме, гаделсезме — барыбер, матур гына итеп үз максатларына ирешергә теләгән төркемнәр файдалана ала. Тышкы «дошманнарга» булган мөнәсәбәтне җиңел генә эчке процессларга да кайтарып калдырып була икәнен аңладылар да алар шуның белән бөтен халыкның җанын җәфалый башладылар. Кызганыч хәл: нәфрәт психологиясе үз фәлсәфи нигезен дә таба. Чаллыдагы Татар иҗтимагый үзәге координаторы З.Әһлиуллин: «Без бүген үз туган телебез өчен көрәштә этләр белән бүреләр кебек булып калдык. Үз теле, үз дәүләте өчен көрәшкәннәрне бүреләр кебек дибез, — көчле якта торган, сораган кулына хәер сәдакасы ала алган татар малаен этк<br>ә саныйбыз. Бүреләр этләргә караганда азрак була. Әмма алар этләрдән рух өстенлеге белән аерылып торалар. Милли хәрәкәттә без, бүре рухы бетмәгән ирләрне берләштереп, этләрне ашарбыз һәм «тулысынча җиңүгә ирешмичә калмабыз». Бу хайванлык психологиясе белән халык мәнфәгате арасында бернинди дә уртаклык юк, чөнки андый психология мәдәни, зыялы халык нигезенә түгел, ә хайвани инстинктларга нигезләнгән була. Мондый «хайванлык фәлсәфәсе» «алдагы җиңүләр» белән рухландырып кешеләргә нәфрәт сабагын укыта. Ягъни теләсә нинди сәяси көрәш рәвешләре һәм ысуллары хакимият башына басу юлында аклана дип әйтергә тырышалар.

Хаким буласы килү — кеше холкының иң гаҗәп бер дәртедер. Ул адәм балаларын төрле-төрле эшләр эшләргә дучар итә һәм бер дә ярамаган юлларга да алып кереп китә. Хаким буласы килгән кеше, үз максатына ирешим дисә, бернәрсәдән дә чирканып тормасын, янәсе, менә хәзер тиз генә тиешле нәтиҗә бирердәй теләсә нинди — антикоммунистикмы ул, коммунистикмы, олуг патшалыкмы (великодержавный), әллә миллиме, монархикмы, диниме — барыбер шул идеологик пәрдәне күз алдына төшереп куя да үз эшен эшли башлый.

Хаким буласы килүнең, әгәр дә ул төп максатка әверелмәсә, әллә ни куркынычы да юк кебек үзе. Ләкин хаким булып алгач, әфәнделәрнең нәфсесе кузгала башлаганы да мәгълүм. Хаким булып тәхеттә утыру хакына ул әлеге халык кальбендәге үч вә нәфрәтне файдалана башлый.

Нәфрәт хисе үз дошманын тапмый калмый. Эзләгәнен таба да ул, һәм ул чакта инде син читтән карап кына тор! Өстен генә булып чыгу кирәк ул нәфрәт хисенә. Аста калырга яратмый ул. Гражданнар сугышы шушы нәфрәт идеологиясенең йомгагы булды. Бүген исә нәфрәт хисе кешеләрне яңа орышларга этәрә бугай.

Чын демократия ул курку-куркытуны һәм нәфрәт хисен кичеп үтү булырга тиешле. Демократия ул — сәяси һәм гомуми зыялыкка ирешү. Аны син җәмгыятькә көчләп тага алмыйсың. Файдасыз гамәл! Демократия дип көрәшеп азапланмыйлар, көрәшкәндә тоталитаризм белән көрәшәләр. Ә демократияне су сибеп үстергән кебек үстермичә булмый — әгәр дә без һәрбер кешене гөл итеп күрә алсак иде, аның һәр яфрагыннан көн саен курку-өркү тузанын сөртеп торырга кирәк булыр иде, башка фикерләргә, телләргә, мәдәниятләргә зур ихтирам саклап, гөлләр кояшка борылган кебек, без дә башларыбызны алар тарафына борырга тиеш булыр идек.

III БАШЛАМ

## Русиянең күрәчәге: җавапсыз сораулар

### *I. Русиянең баганаларын кем какшаткан соң?*

Нәрсә соң әле ул Русия? Бу сорауны әле кичә генә беркем дә беркемгә куймый иде шикелле. Сәясәтчеләрне дә, халыкны да аерып тормастан әйтәм монысын. Олуг урыс патшалыгы бетте, дөньядагы олы кешеләрнең фикерен гел дулкынландырып торган Бөек Мәдәният тәмам! Олы Русия үзенә бернинди дә яңа фикер бирә алмаган яңа җитәкчеләре белән берьялгызы аерым утырып калды.

Русиядә бара торган тормышны «шулай булырга тиеш иде инде ул» дип тә аңлатырга була иде. Империяләр бетәргә тиеш. Чынында да, бөтен империяләр дә таркалгач, Русиягә генә чират җитми торуы гаҗәп булыр иде. Мәсьәлә ачык шикелле. Хәлбуки ничек итеп әле ул Русия, 1917 елгы һәлакәтләрдән арынып, аягына торып баса алган да «совет» исеме белән үзен яңарта алган? Һәм бу хәлнең безнең көннәрдә дә яңадан булу ихтималы юкмы?

Русия патшалыгының фикри нигезләре Казан патшалыгын яулап алу һәм аннан соң мәскәүләрнең бүтән җирләрне яулап алуына кайтып кала. Ул чакларда «Мәскәү ул — өченче Рим» дигән носарилар дине (православие) бөтендөнья әхвәленә бик нык тәэсир итә дигән урыс җәмгыятенең җәмигълыгы (соборный) һ.б. турындагы әкиятләр бик нык урыс халкы аңына тукылып торыла. Ә дәүләт структуралары исә Алтын Урдадагы корылышны үзендә урнаштыра. Хаклыкка хилаф булмасын өчен әйтеп үтик, Явыз Иван (IV) заманында урнаштырылган тәртипләр яңа патшалыкка яңа вәхши хосусиятләр дә бирә. Ә аннан соңгы патшалар моңа үзләреннән өлеш кенә кертә киләләр. Петр I дән соң Алтын Урданың йогынтысын Польша үрнәге йә булмаса Көнбатыш Украина вариантындагы Көнбатыш сәясәте алыштыра. Русиянең сәясәте яңадан-яңа җирләр яулап алу, халыкларны буйсындырып экономиканы шул җирләрдә экстенсив үстерү, патша исеме һәм дә гаскәр көче белән атлы казаклар һәм кәгазь түрәләре ярдәмендә бөтен кешеләрне бөкрәйтеп йөрергә юнәлдерелгән иде.

Демократия башлангычлары, Русиягә капиталистик мөнәсәбәтләргә ияреп кереп, 1905 елгы һәм аннары — 1917 елгы вакыйгаларга килеп тоталә. Инкыйлаб алдында булган дәверләр аңнарны гомумдемократик һәм социалистик фикерләр белән аклый, бик тә күркәм урыс мәдәниятен хасил итә. «Байлар оясы» дигән әүвәлге «багана»ларны капиталистлар да, язучылар да бик нык какшаттылар; алар патша хөкүмәте белән «ризасызлыкның соң чигенә җиттек» дип тәкрарладылар. Һәм империянең вәйраны өчен бер каты селтәнеп алу гына кирәк булган икән — Беренче бөтендөнья сугышы кабынып та китә.

Урыс илендә социалистик идеяләр матур гына иңеп тә киткән булган иде шикелле. Чөнки ул идеяләр бергә-бергә эшләү-яшәү гадәтләрен алга сөрә иде, урында утыручыларга карышмаска кирәк, дия иде, тигезлек кирәклеге турында әйтә иде. Социализм Русия өчен бер дә чит нәрсә түгел иде. Киресенчә, Русия өчен чит нәрсә демократия булды.

Русиянең изелгән халыклары «революция» дигән сүзне үз якларына файдаланмакчы булганнар иде. Ләкин Финляндия белән Польшадан башкалары ничек булган, шул хәлдә империядә кала бирделәр. Моңа булышучы факторлар: халыкларның үз эчләрендәге сыйнфый аерылулар; большевикларның демократик лозунгларына ышанып, халыкта милли азатлыкка ирешү өмете уяну, «ак» армиянең һаман саен «бердәм һәм бүленмәс Русия» дип тәкрарлавы, Мәскәүнең «әйбәт» баш эшләтүе һәм Кызыл Армиянең — империя структураларын тиз генә үз урынына китереп утыртуның тугры чарасының куәте булды.

Кызыл гаскәр куәте генә түгел, большевикларның идеяләре дә күркәм иде. Октябрь инкыйлабы империализмга, колониализмга каршы чыкты, борынгы һәм каты тормыш тәртипләрен шатырдатып ватты. Социализм гаделлек һәм тигезлек вәгъдә итте. Яңача иде бит болар, күркәм иде. Русиянең олуг патшалык (великодержавный) фикере бөтенләй башка рәвеш алды — дөнья революциясе ясап, имештер, җир йөзендә тигезлек һәм гаделлек урнаштыру.

Хаклык хакына, ул елларда башка милләтләр интеллигенциясендә урыс мәдәниятенә бик тирән ихтирам булганлыгын әйтми китеп булмастыр. Урыс язучылары, галимнәре, сәясәт әһелләре милләтчеләр өчен бик зур абруй иделәр — алар алардан күп нәрсәгә өйрәнделәр һәм аларга ышанып яшәделәр. Бик күпләр шушы бөек дәүләттә торулары, аның бөек әдәбиятына һәм мәдәниятенә ни дәрәҗәдәдер катнашлары булу белән горурлана иделәр. Нишләсеннәр соң? Коммунистик идеология кешеләрне рухландыргандыр да бергә туплагандыр инде...

Бүген инде бу факторлар юк. Урыс мәдәниятенең элекке абруе нык төште: беркемгә дә һәм бернәрсәгә дә ошатып эшлисе калмады. Урыс язучыларының съездлары ваклыклары һәм фантазия юклыгы белән шаккатыралар. Распутиннарның нотыклары, Куликово сугышы белән башланып, евангелие вәгазьләре белән тәмамлана. Урысның миллилеге тәре үбүләргә, җәзалап үтерелгән Русия монархы турында авыз суларын

корыта-корыта сөйләүләргә һәм «меңьеллык» патшалыкны саклап калырга өндәүләргә кайтып калды, һәм бу сүзләрне моннан йөз еллар элек кенә ярты дөньяны үзенә каратып торган милләт вәкилләре сөйлиләр. Ә бит ул чактагы интеллигенция андый абруйны патшаларга мәдхия укып түгел, ә демократия идеяләрен яклап яулап алган иде. Толстойлар, Достоевскийлар, Чеховлар, урыс публицистлары һәм XIX йөз ахыры — XX йөз башы фәйләсүфләре патша Русиясе гадәтләрен тәмләп сөйли алалар идеме соң?! Бүген исә урыс әдәбияты шундый дәрәҗәгә төште ки, ул Русия бик авыр кичерә торган фаҗигане дә яңарыш дип исәпли.

Русиянең шул атом-төш потенциалыннан башка бер юньле бөек нәрсәсе калмаган, ахры, дигән тәэсир туа...

Революциядән соңгы Русиядән аермалы буларак, бүгенге Русиянең бер генә идеологиясе дә юк, ә демократия турындагы гомуми лозунглар һәм көне-төне коммунистларны хурлау белән генә этник һәм мәдәни яктан шундый чуар илне берләштерү мөмкин түгел. Антикоммунизм киң халык массалары өчен идеология булып тора алмый, ул бары тик үткәндәге идеологияләрне җимерергә генә ярый, хакимлеккә омтылучы кешеләргә бер корал гына ул. Хакимлек ул күп кешеләр өлеше түгел. Төп массалар исә дөньяга ачык күз белән карый, аңа әхлакый кыйммәтләр, иман кирәк. Марксистик фәлсәфә юк икән, аның урынын башкасы алыр. Ләкин Русия халкына бүген нәрсә тәкъдим итәләр соң? Антикоммунизм һәм православие! Беренчесенең кызыгы юк инде, ә икенчесенә бөтен кеше дә иман китерергә ашкынып тормый...

Урыс интеллигенциясе алдынгы идеяләр чыганагы булудан туктады, ул хәзер үзе бөтенесенең — валютасы йөри торган теләсә кайсы илнең — АКШның, Төркиянең һ.б. авызына карап тора. Русия, милли горурлыгын югалтып, теләсә кайдан ярдәм сорый. Бөтен җир йөзе буйлап хәер сорашып йөргән ил башкалар өчен үрнәк булып тора аламы соң инде?! Русия гап-гади таркалуга дучар.

Коммунистларны туйганчы сүгәргә мөмкин, ләкин кимчелекләре җитәрлек булган булса да, алар бар халыкларны тыгыз кыршау белән «совет берлегенә» берләштереп куйган кыйммәтләр булдыра алдылар. Революция алды концепцияләре җыелмасында социалистик концепция тарихи традицияләр белән иң нык бәйләнгәне иде. Ул Русиянең тирәндә яткан нигезләренә җавап бирә иде. Бүгенге көндә идеологик бушлык барлыкка килде, ә бу безнең борынгыдан килгән дөньяга карашларыбызны кире кайтара. Әмма бит һәр халыкның үз тарихы була. Шуңа күрә кешеләр үзләренең этник үткәннәрен искә төшерә башладылар һәм шуның белән бергә, «милли тормыш белән канәгать» булып, республикалары мәнфәгатьләре белән яшәргә тотындылар.

Урыс идеясе бик аяусыз кризис кичерә. Урыс милләтенең төп баганасы булган православие базар мөнәсәбәтләре һәм демократия белән начар килешә һәм шуңа күрә хәтта урысларның үзләрен генә берләштерү вазифасын да үз өстенә ала алмый. Демократия урыс традицияләренең тамырына балта чаба, чөнки ул традицион тоталитар фикерләү белән хакимиятнең үзәкләштерелгән структурасына каршы төшә, коллективизм урынына индивидуализм һәм шәхес ирекен тәкъдим итә, башка илләр белән «хәрби узыш» урынына гади хезмәт белән шөгыльләнергә мәҗбүр итә. Демократия Русия алдына катлаулы мәсьәлә китереп куйды.

Русия җитәкчелегенең гомуми концепциясен тикшерә башласаң, «ә ул Русиянең бөтенлеген сакларга тели микән соң» дигән сорау алдында каласың, һәм демократия ягында торган хәлдә «меңьеллык» Русияне саклап калуны яклап чыгу мөмкин эшме ул?

*II. Русиянең чик буйлары кайдан үтә?*

Борылыш дәверләре кешеләрне кайвакыт шулкадәр бутап бетерә ки, алар инде сәбәп белән нәтиҗәне дә аермый башлыйлар. Менә Русиядән дә Татарстан адресына, имештер, ул мәңгелек корылмаларны җимерә, дип, күпме нәгърәләр яудыралар. Көтелмәгән афәттән аптырашта калган урыслар беркатлылык һәм еш кына ихластан «шундый әйбәт кенә яшәгәндә...» дип куялар. Аларның уфтануларын аңлап була: алар күп кенә яктан үзләре дә үз олуг патшалыкларының корбанына әверелгәннәр иде.

Империяләрнең табигый оешкан полиэтник дәүләтләрдән аерымлыгы шунда ки, аларда инде оешкан булган халыкларны көчләп «берләштерәләр». Моңарчы үз дәүләтләре булмаган этнослар мәгълүм бер дәрәҗәдә үз язмышлары белән әле килешеп тә яшәргә мөмкин, ләкин булган дәүләтләрен югалткан халыклар репрессив органнарның бераз йомшаруы белән империя нигезләрен күккә очырырдай шартлаткыч матдәгә әвереләләр. Шуңа күрә империя үзенең бөтенлеген саклап калу өчен көч белән ассимиляция сәясәтен үткәрергә тотына. Ләкин бу сәясәт, мәгълүм нәтиҗәләр бирә алса да, мәсьәләне принципта хәл итә алмый.

Моннан беренче менә мондый йомгак килеп чыга: көчләп берләштерелгән халыклар табигый берлек хасил итә алмыйлар. Тормыш күрсәткәнчә, монда дәүләтнең үзенең күпме яшәгән булуының әһәмияте юк икән. Мәсәлән, болгарлар Төркия протектораты астында — 700 ел, эстоннар немецлар астында — 500 ел, ә аннары әле урыс хакимлеге астында шактый тордылар, тик барыбер азатлыкка сусауларын онытмаган булып чыктылар.

Урыс милләтенең үзенчәлеге шунда ки, аның тормышы гасырлар буе яңа территорияләр яулап алуга җайланган иде. Бередә гади халыкның моннан файда күрү-күрмәвенең әһәмияте дә юк иде. Язмыш аңа нәкъ менә шундый миссия әзерләгән иде. Бер үк вакытта урыс милләте ике милләткә аерылган кебек булып чыкты: колонизация җимешләре белән туенып яшәүче «башкала» милләтенә һәм үз хәлләре дә буйсындырылган халыклар хәленнән әллә ни аерылып тормаган «провинциаль» милләткә. Санкт-Петербург милләтнең түгел, ә дәүләтнең ясалма башкаласы булды — аны чит ил кешеләре урыс сөякләре өстенә кордылар. Революциягә кадәр урыс мәдәниятен Мәскәү гәүдәләндерә иде, ләкин совет чорында ул тулысы белән бимиллиләнеп бетте (денационализацияләнде)... Моннан тагын бер йомгак ясап була. Өлкәләрдәге урысларның «тәртибе» Мәскәүдә утыручылар уйлаганча булмаска да мөмкин.

Планетаның алтыдан бер өлешен шундый тизлек белән яулап алу урыс милләтен үз тарихи ватанын онытуга китерде. Киев хәзер башка дәүләттә калды. Мәскәү исә иксез-чиксез үз проблемаларына кереп баткан сәер бер конгломератка әверелде. Кара туфраклы булмаган җирләргә беркемнең дә исе китми. Гасырлар буе барган колонизация дәверендә Мәскәү кенәзлегеннән бик еракта чакта барлыкка килгән яңа этник шәкелләр дә үзләштерделәр. Ул гына да түгел, алар яңа җирләрдә яңа мәдәниятләр белән берегә башладылар. Гомумән, урысларны ачык милләт дип әйтеп тә була. Алар башка халыклар белән бергә-бергә яши алалар, һәм шуңа күрә өченче йомгакны да чыгарып була: урыслар республикаларда андагы төп халыклар белән бергә үзбилгеләнергә әзер халык, алай гына да түгел, аларның Ерак Көнчыгыштамы, Себердәме һ.б. җирләрдәме Мәскәүдән бәйсез булган мөстәкыйль дәүләтләр төзеп ташлаулары да бик ихтимал.

Югарыда әйтелгән факторлар Русиянең таркалу процессын аңларга һәм туачак дәүләтләрнең мөмкин булган чик буйларын фараз кылырга ярдәм итә.

1992 елга кадәр Русия юридик мәгънәдә СССР белән тәңгәл килә иде. Монда ике нәрсәне истә тотарга кирәк: беренчедән, урыслар халыкара аренада нәкъ менә СССР йөзендә китереп куела иде (дәүләт теле һәм мәдәнияте белән). Чит илләрдә сүз арасында да, матбугатта да СССРны — Русия дип кенә, ә барлык совет кешеләрен урыслар дип кенә йөртә башладылар, һәм бу дөреслеккә әллә ни хилафлык та түгел иде. Икенчедән, РСФСР ул чакларда шәхсән дәүләт түгел һәм аның суверенитеты юк иде. Хәер, аның мөстәкыйль Компартиясе дә юк иде, бу үзе генә дә, асылда, СССР белән Русиянең тәңгәл килүен һичшиксез исбатлап тора иде.

РСФСРның суверенитет игълан итүе һәм аннан да битәр СССРны юкка чыгару тарихи урнашкан Русиянең таркалуын башлап җибәрде. Бүгенге Русия Федерациясенең тарихи Русия ролен дәгъва кылырга нигезе юк. РСФСР, гомумән дә, Сталинның субъектив конструкциясе һәм аның үзенең бүленмәс булуына хакы элеккеге СССРныкыннан бер тамчы да артык түгел, һәрхәлдә, Украина, әйтик, Татарстанга яки Себергә караганда Русиягә җирдәшрәк. Юк дигәндә дә, Киев бит кайчандыр борынгы Русьның башкаласы булган, ә Казанны алай дип кем әйтә алыр икән?!

Русияне СССРны саклаганда гына саклап калып булыр иде: М.Горбачев бу юнәлештә тырышып та карады, — өлешчә Союз договоры төзеп һәм референдум үткәреп. Хәлбуки аның хатасы реформаларының ярты-йортылы булуында, милли мәсьәләне тулаем хәл итәсе урынга төрле функцияләрне мәркәз белән Союз республикалары арасында бүлешергә азаплануында иде. Ә референдумы бөтенләй дә файдасыз бер акт иде, чөнки этник проблемаларны урыслар күпчелеге фикерен ачыклау белән хәл итеп булмасы көн кебек ачык лабаса.

Ә шулай да Русия өчен иң фаҗигале хатаны М.Горбачев түгел, ә СССРны торкатып, Б.Ельцин ясады. Хакимлек өчен көрәш демократларның башын шулкадәр әйләндерде ки, алар вакыйгаларның кай якка таба китәсен дә фараз итә алмый башладылар — аларга дәүләт түгел, ә шунда хакимлекне алу һәм моңа бик тиз ирешү кирәк иде. Анекдотка охшаш ситуация килеп чыкты: демократлар Русиянең суверенитеты өчен дәүләт атрибутлары да булмаган урыс милләтенең мескенлеге әләмен күтәреп көрәшә башладылар. Алар хакимияткә ирештеләр, әмма элекке Русияне югалттылар, ә яңа Русияне төзүе искесен саклауга караганда катлаулырак шул ул.

Бүген Русиянең төгәл чикләрен сызып чыгу мөмкин түгел. Халыкларның үз ирекләре белән Русия дәүләтенә килеп кушылулары турындагы әкият реаль дөньядан хыял дөньясына чыгып яшәүче беркатлы һәм бик садә кешеләргә генә ярый. Төрле территорияләрнең «үз ирекләре белән» Русиягә кушылуларына багышлап куелган төрле-төрле һәйкәлләр алар — коллык һәйкәлләре, һәм аларны әүвәлге номенклатура куйды, ә хәзергеләре тырышып саклый килә. Төп, тамыр халыкларның Русиягә исәп-хисап китереп тоттырыр заманаларга күп калмады инде, менә шунда урысның үз җире Бальзакның атаклы «җәйрән тиресе» сыман бөрешкәннән-бөрешә барачак...

Урыс милләтенең этник сибелеп утыруы сәясәттә шактый зур роль уйнаса да, хәлиткеч фактор һәм бигрәк тә дәүләт чикләрен билгеләүче фактор булып тормый. Инде бүгенге көнгә үк 26 миллион урыс кешесе Русия Федерациясеннән тышта калды, һәм аларның, әйтик, Казахстан өлкәләрендә тоташ-тоташ урнашкан

булуларына карамастан, бу хәл Русия Федерациясе чикләрен билгеләүгә бер дә тәэсир итмәде. Ә ник соң әле бу Русия белән Татарстан мөнәсәбәтләренә йогынты ясарга тиеш ди?!

Урыс милли идеясе кризис кына кичереп калмый, ул принципта демократия белән сыеша алмый һәм шуңа күрә ул башка идеология белән алыштырылмый калмастыр. Әлбәттә, үткәнне сагынучы национал-патриотлар әле халыкның бер өлешенең фикерен үз якларына шактый каратып торырлар, әмма шуның белән бергә яңа идеология дә туып килә. Ул конкрет регионнарга: Ерак Көнчыгышка, Себергә, Донга һ.б.ларга нисбәтле. Урыс өлкәләре дә, гомумән алганда, Татарстан үткән юлны кабатлаячаклар: башта алар, безне Мәскәү эксплуатацияли һәм безнең Русия колониясе булып яшисебез килми, диячәкләр. Аннары алар күпме биреп, күпме генә алганнарын исәпли башлаячаклар, аларның нинди зур ресурслары булуын һәм сәяси мөстәкыйль булсалар, алардан файдалана беләчәкләрен искә төшерәчәкләр, бер каналлы бюджет, тышкы экономик мөнәсәбәтләргә хокук таләп итә башлаячаклар һәм, ниһаять, үзләрен мәркәз дәгъваларыннан аралый торган үз законнарын кабул итәргә тотыначаклар...

Бөтен дөньяда хакимиятне дезинтеграцияләү тенденциясе барганлыгын да әйтеп үтик. Хәтта федератив мөнәсәбәтләр шундый камиллеккә ирешкән Германия белән АКШ кебек илләрдә дә мәркәз белән федераль хөкүмәте федерация субъектлары булган штатлар һәм төбәкләр арасында каршылыклар сизелеп-сизелеп ала. Аурупаның бөтен илләрендә дә диярлек провинцияләр ил эчендә генә түгел, халыкара мөнәсәбәтләрендә дә һаман күбрәк мөстәкыйльлек яулый баралар.

Региональ мәнфәгатьләр һәм тулаем региональләштерү идеясе Русияне идеологик тупиктан тартып чыгарырга мөмкин.

Русия торган саен эфемеррак төшенчә була бара, ул төшенчә шактый ук анык булмаган эмоциональ лозунгларга кайтып кала. Русияне әүвәлге төсендә саклау мөмкинлегенә бер генә өмет тә юк. Аның якынча гына чикләрен билгели ала торган хокук нормалары юк. Әгәр дә Русия җитәкчелеге реаль федеральләшү юлына басса, ул чакта ни буласын төгәлрәк фаразлап булыр иде. Әмма Русия җитәкчелеге федератив мөнәсәбәтләргә омтылмый шикелле. Соң, ә Русияне саклап калырга телиме соң ул?

### *III. Федерацияме, конфедерацияме, әллә бәйсез дәүләтләрме?*

Русия федерация яисә конфедерация дә була алыр иде, һәм бәйсез дәүләтләр булып таркала да ала. Теоретик яктан өч юлның өчесенең дә булуы ихтимал. Аларның берәрсенең тормышка ашуы өчен конкрет объектив һәм субъектив шартларның туры килүе генә кирәк.

Соңгы елда матбугатта Русиянең милли-дәүләтчел корылышы хакында буа буарлык аналитик мәкаләләр чыкты. Аларның күбесе олуг патшалыкны (державаны) сакларга иде диген ялкынлы өндәмәләргә кайтып кала. Ксения Мяло үзенең «Бүре чокыры» дигән мәкаләсен менә мондый сүзләр белән тәмамлый: «Ә шуның өчен, әгәр милли яшәвебез хакына ихтыярыбыз уяна икән, Русияне без, аны нинди генә вак кисәкләргә телгәләп бетерсәләр дә, кире җыеп алмый калмабыз. Чөнки безнең җаныбыз — аларны, ә алар безнең җанны, ягъни үз җанын танып алырлар». Матур әйтелгән әйтелүен. Ләкин мондый мәкаләләрне укыгач, Русия аналитиклары һаман да шул борынгы «ә бәлкем!», «ә бәлкем, барып чыгар әле!» дигән сүзгә таяналар бугай дигән тәэсир кала. Ләкин бит Кара диңгездәге төп портлары да югалды ич инде, көньяк чик буйлары Әстерхан белән Ырынбурга таба чигенде, яңа Кавказ сугышы кызганнан-кыза бара. «Артыбызда Мәскәү ләбаса» дигән тарихи чакыру хәзер халыкка элеккеге тәэсирне ясамавы да бар.

Компромисс эшләүче күп кенә сәясәтчеләр һәм публицистлар Русиянең славян һәм төрки халыкларын, ислам һәм носари (христиан) мәдәниятләрен кушып ниндидер бер симбиозга әйләндерүче Ауразиячел дәүләт булуы турында тезис уйлап чыгардылар. Аларның нәрсә әйтергә теләгәннәрен сизүе кыен түгел: имештер, йөз еллар бергә яшәү дәверендә татар һәм урыс этнослары тәмам кушылып беткәннәр, һәм безнең, янәсе, бүлешер нәрсәбез юк. Үзләре теләгән теләкне һаман кабатлап торып, алар кешеләрне генә түгел, вакыйгалар барышын да сихерләмәкче. Беравыктан үзләренең шул «сихер»ләренә җүләр кебек үзләре дә ышана башлыйлар. Ләкин чынбарлыкның бите бөтенләй андый түгел. Коми халкының бер генә милли мәктәбе дә юк. Кая инде монда «халыклар союзы»на урын?! Шушы бер генә факт та башкаларын карап та тормаска безгә нигез бирә. Русиядә халыклар хокукларының ни дәрәҗәдә бозылып килүен фаразда гына күзалларга мөмкин. Бу мәсьәләнең әле көн тәртибенә калкып чыгасы күренеп тора, менә шунда инде күп халыклар Русиягә үз исәп-хисапларын китереп төртерләр.

Субъектив фактор тарихта гаять зур роль уйный. Фиркаләрнең, идеяләр һәм юлбашчыларның вакыйгалар барышына ни дәрәҗәдә йогынты ясавын белер өчен Ататөрек белән Ленин принципларын чагыштырып карау да җитә. Ул ике империя дә бер үк вакытта диярлек тугарыла башлыйлар. Хәлбуки төрекләрнең читтәге территорияләрдән баш тартырга ирлеге җитте һәм үз җирендә милли дәүләт корып куйды, больше-

виклар исә бар булган көчләрен әлеге территорияләрне саклап калырга һәм империяне торгызуга юнәлттеләр. Тарих бүген Русия лидерлары алдына шул ук сорауны китереп куя. Йә, бу юлы алар нишләр икән?!

СССРны таркату, объектив рәвештә өлгергән булган булса да, империягә каршы хакыйкатьләр белән терәтелгән түгел иде, һәм шуңа күрә дә Б.Ельцинның бу акциясе Русия җитәкчелегенең йөзен күрсәтми. Сүз арасыннан әйтик, Союз договорының проекты, республикаларны «сорт»ларга бүлү сакланып калган очракта да, милли-дәүләтчел корылышны федеральләштерүгә таба бер адым була иде.

Русиянең Федератив килешүе бу сәясәтнең аңлы дәвамы була алмады, киресенчә, ул суверенлашу процессларын бүлеп шактый күп империя структуралары калдыруны — Союз һәм Русия министрлыкларының түзалмаслык салымнарны, тышкы икътисади элемтәләрне бер мәркәз кулына туплауны һ.б. саклап калу максатын күз алдында тотты. Тарихи документ буларак, Федератив килешү бик тә гыйбрәтле һәм аны ныклап торып тикшерәсе, аннан сабак аласы иде.

Иң элек бер гади генә сорауга җавап биреп карыйк: Русия нинди иганә (урынлаштыру) документларына таянып тора соң? Монархия алыштырылды, тоталитаризмны кире кактылар, демократия курсы игълан ителде, ләкин Иганә мәҗлесен (Учредительное собрание) җыеп азапланмадылар. РСФСРны төзи башлау шулай кузгалып киткән 1918 ел документларына да (Русия халыклары хокуклары декларациясе һ.б.) әйләнеп кайтып булыр иде дә, ләкин аларда Федерация субъектлары буларак, өлкәләр, крайлар һәм шәһәрләрнең катнашуы каралмаган. Шулай итеп, яки Федератив килешүдән субъектлар сыйфатында административ берәмлекләрне алып ташларга кирәк була, ул чакта Русиянең хокукый нигезе барлыкка килә, яисә Русияне өр-яңадан урынлаштырырга гына кала. Русия җитәкчелеге өченче һәм иң яман вариантны сайлап алды шикелле — бернәрсә дә урынлаштырып тормыйча гына, иске унитар бинага псевдодемократик игъланнар эләләр.

Өлкәләр, крайлар һәм шәһәрләр белән алай санлашып торуның нигә кирәге бар соң? Эш шунда ки, аларның үзләре чикләрендә яшәүче халыктан урынлаштыру вәкаләтләре алганнары юк. Алар бары тик административ берәмлекләр генә, аларның үзләренең югары хакимиятләре, конституцияләре һәм үз кануниятләре юк. Шунлыктан аларның җитәкчеләренең Федератив килешүгә кул куярга хаклары да юк. Менә шушында инде Русиянең бөтенлегенә куркыныч яшеренеп ята. Шундый әһәмиятле мәсьәләдә аларга үз белдегенчә эш кылырга рөхсәт ителгән икән, башка мәсьәләләрдә дә алар хаксыз юлдан китеп бармаслар дигән гарантия юк. Ул гына да түгел, Федератив килешү, республикаларны административ берәмлекләр белән тигезләп, соңгыларына «сепаратизм»га кануни сылтау да бирә. Хәзер өлкәләр, крайлар һәм шәһәрләр, дәүләт суверенитеты турында декларацияләр кабул итеп тормыйча, референдумнар үткәреп турыдан-туры президентлар сайлап маташмыйча, конституцияләр һәм башка законнар кабул итмичә дә, үзләренә суверен республика хокукларын таләп итә алалар. Carte blanche аларга нәкъ менә федераль хөкүмәт тарафыннан, Русияне таркатуга китерә торган уйлап җиткерелмәгән адымнар нәтиҗәсендә бирелде.

Әйтелгәннәрдән мондый нәтиҗә килеп чыга: Федератив килешүне Русияне урынлаштыручы документ дип карап булмый, асылда, ул үзәк хөкүмәтнең административ берәмлекләр белән хокукларны яңадан бүлешү турында килешү генә. Килешүе дә әле канәгатьләнерлек түгел, чөнки, аңа карагач, мәсәлән, җир асты байлыкларының кем кулында — субъекттамы, мәркәздәме икәнен дә ачыклавы кыен. Хокукый документлар катлаулы мәсьәләләргә ачык җавап бирергә тиешләр. Шулай булмаганда, алар каршылыклар чыганагына әвереләләр.

Федератив килешү — олуг патшалыкның бүленмәслеге турында «автономияләр» имзалары белән беркетелергә тиешле документ, үзенә күрә «матушка Россия»гә тугрылык турында ант иттерүче сәяси акт булып чыкты. Бер үк вакытта федераль хөкүмәт М.Горбачевка караганда бер адым арткарак атлады һәм 20 нче еллар практикасына кире кайтты. Аерма шунда гына: әгәр большевиклар, бу процедураны республикаларны декретлаштыру дип атап, автономияләргә Федератив килешү биргәнгә караганда күбрәк вәкаләтләр биргән булсалар, Русия җитәкчелеге Көнбатыш колагына ятышлы терминология артына сыенырга мәҗбүр булды. Ләкин мондый сүз зинасы Русиянең бөтенлеген дә җимерергә мөмкин.

Федератив килешү тагын да икенче бер гади генә сорауга җавап сорый: ул аерырга мөмкин булмаган килешүне, ягъни федерациядән чыгу мөмкинлеген калдырмаган документны, килешү дип исәпләп буламы соң әле? Азатлык азатлык инде ул. Аны мәркәз ирке, аның хәрәкәтләре иркенә куелган азатлык дип карап кала алмыйсың. Әгәр дә милли сәясәттә халыкларның аерылып чыгуга кадәр үзбилгеләнү хокукы каралмаган булса, ул чакта Русия беркайчан да демократик та, федератив та була алмаячак. Алай гына да түгел, аерылып чыгу хокукын кире кагу үзеннән-үзе республикаларның территорияләрен һәм гражданлыкны да кире кагу булып чыга. Федерация унитар дәүләттән шунысы белән аерыла да: ул «бүленә ала торган» була һәм суверен территорияләрдән тора.

Федерация ул тасвирламасы буенча яңа дәүләт хасил итә торган дәүләтләр союзы була. Союзның шулай ук суверен дәүләтләрнең ихтыяри һәм тигез хокуклы берләшмәсе икәнлеген искә төшереп үтү дә зыян-

лы булмас. Барлык төшенчәләрне дә төрлечә, конъюнктурага карап аңлата торган безнең илдә гел искә төшереп торырга туры килә: теләсә нинди дәүләт тә, һичшиксез, суверенлыкка ия була, ә суверенлык исә бәйсезлек дигән сүз ул, ә килешүләр субъектлар тарафыннан «астан башлап» төзелә. Инде өстән төшерелгән «килешүләргә» килсәк, андый «килешүләр» гомумән дә була алмый, федерацияне өлкәләр кора алмый, чөнки аларның, дәүләтнең административ берәмлекләре буларак, урынлаштыру (иганәчелек) вәкаләтләре юк һ.б.

Федератив килешү — дәүләт корылышы турында бөтен нормаль күзаллауларны үзгәртеп, бозып бетергән юридик корама ул. Федерация субъектлары итеп Мәскәү һәм Санкт-Петербургны кертү үзе генә дә ни тора! Алайса, ни өчен соң Екатеринбургны яисә Түбән Новгородны да кертмәскә икән? Нәрсәсе белән алар Петербургтан начаррак? Элегрәк халык саны бер миллионга җиткән шәһәрләрдә метро салу гадәте бар иде. Бу иске традицияне шәһәрләрнең субъектлыгын билгеләүдә дә кулланыгыз алайса: 1 миллионнан арттыңмы — РФгә кер, 10 миллионнан артсаң — БМОга туп-туры!

Әйтелгәннәр өлкәнең яки шәһәрнең федерация субъекты була алмыйлар дигән сүз түгел. Әлбәттә, була алалар. Ләкин әгәр дә алар моңа дәгъва кылалар икән, ул чакта алар үз халкыннан иганәчелек вәкаләтләре алырга тиешләр икенче төрле әйткәндә, барлык атрибутлары булган тулы бәяле дәүләтләр булалар.

Федератив килешүнең мәгънәсезлеген аның төп текстына капма-каршы килә торган Башкортстанның махсус протоколы булуы да ачык күрсәтеп тора. Теләсә нинди килешүнең мәгънәсе дә килешүче якларның мәнфәгатьләрен килештерүдән тора. Килешү принципта аның мәгънәсен үзгәртә торган нindiдер кушымталар белән була алмый. Әгәр аның белән берәрсе риза булмаса, яңа килешү төзелә.

Ниһаять, үз-үзебезгә өченче, бөтенләй беркатлы сорау бирик: федерацияләрне ни өчен урынлаштыралар да, аларның мәгънәсе нидә? Дөнья тәҗрибәсе шуны күрсәтә: федерацияләр аның иганәчеләренең (субъектларының) суверенлыгын тәэмин итү өчен төзеләләр. Нәкъ менә шул принцип йөз елларга Швейцария һәм АКШның стабильлеген тәэмин итте. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: АКШ Конституциясендә беренче үк төзәтмә — кеше хокуклары турында — билль-штатларда мәрдәннәрнең (гражданнарның) хокукларын федераль хакимият кысуларыннан саклау өчен кабул ителде һәм бары соңгы 70 елда гына алар кеше хокукларын яклау һәм саклау дигән яңа аңлатма алды. Русиядә исә бөтенесе дә киресенчә эшләнде: федераль хөкүмәтнең «суверенитетын» гарантияли, аның хокукларын субъектлар дәгъвасыннан аралый торган документка кул куйдылар. Шуңа күрә үз суверенитетлары язмышын кайгырткан Татарстан, Башкортстан, Якутия һәм башка республикаларның тәртибе бик тә мәгънәле аклана. Мәгълүм ки, Татар республикасын 1920 елдагы декретлардагы хокукларын кире кайтарган өчен сепаратизмда гаепләргә маташалар. Ләкин аннары 1937 ел килде, һәм әлеге хокукларның эзе дә калмады. Федератив килешү яки Русиянең хакимият структуралары Татарстанга яңа диктатурадан гарантияләр бирә аламы соң? Әлбәттә инде, юк. Принципта андый гарантия булып Татарстан белән Русия арасында ике яклы килешү белән беркетелгән чыгу хокукы гына һәм шулай ук Татарстанның халыкара танылуы гына тора ала.

Әгәр дә Русиянең бөтен һәм бүленмәс булуыннан чыгып карасаң, ул чакта Татарстан Республикасының БМОга алынуы аны җимерү кебек күренер иде. Ләкин әгәр үзара мөнәсәбәтләрнең күптөрле конфедератив-федератив рәвешләрен тану нигезендә Русия реформаларга чын-чыннан омтылганда, Татарстанның суверенитеты Русиянең яманаты чыккан бөтенлеге белән бик иркен сыеша ала. СССРны искә төшерик: анда Украина белән Белоруссия БМО әгъзалары иде, һәм бер генә юрист та СССРның бөтенлегенә шик белдермәде.

Бүгенге көндә Русиянең бөтенлеге һәм бүленмәслеге тарихи традицияләр яисә инерция аркасында гына сакланып килә. Демократия принциплары, Русиянең әүвәлге тарихи урнашкан карашлары һәм нигезләре хакимиятне монарх яки генсек йөзендә үзәкләштерү белән капма-каршы килә. Б.Ельцинның халык тарафыннан турыдан-туры сайлануы мәгълүм дәрәҗәдә бөтен Русияне гәүдәләндерә һәм лигитимлык элементын хасил итә, ләкин президент монарх түгел бит әле, һәм ул үзе турында: «Дәүләт ул мин!» — дип әйтә алмый. Шуңа күрә Русиянең хокукый нигезе бик тә какшаучан. Азмы-күпме җитди булган теләсә нинди сәяси вакыйганың илне котылгысыз таркатып ташлавы бар. Үз заманында кадет Милюков: «Бөтен һәм бүленмәс Русия» лозунгысы антибольшевистик блокны харап итте», — дигән иде. Тарих бик гыйбрәтле дә бит, ләкин аның сабакларына бик колак салып бетермиләр шул.

Федератив килешү кабул итеп, Русия җитәкчелеге әүвәлге империяне нормаль федеральләштерү мөмкинлеген юкка чыгарды. Теләсә нинди Федератив килешүнең мәгънәсе шунда: ул, күптөрле коллизияләрне истә тотып, дәүләт эчендәге мөнәсәбәтләр үссен өчен кысалар урнаштыра. Федератив килешүгә кул куйганда ук Татарстан белән Чечняны читтә калдырды, ә Башкортстан өчен махсус кушымта әзерләнгән иде. «Кысалар» республикалар, өлкәләр, шәһәрләр башлыклары имзаларының карасы да кибеп бетмәстән шартлап сынды. Ләкин шуның белән федераль хөкүмәт үзенең сәләтсез икәнлегенә кул куйды. Төньяк Кавказдагы конфликтлар бу килешүнең кирәген бөтенләй бетерде, чөнки аның нигезендә азмы-күпме җитдирәк

проблемаларны җайга салу мөмкин түгеллеге бик ачык күренде. Федератив килешүнең бер генә яшәү мәгънәсе калды: ул республикалар һәм өлкәләр өчен мишеньгә әйләнде.

Русияне федерация итеп үзгәртү өчен мәгълүм сәяси ихтыяр кирәк, ә ул Русия җитәкчелегендә юк, ахрысы, ул үзенең хакимлеген саклап калу турында уйлый, ә дәүләтнең киләчәге турында кайгыртмый.

Килешү «кысалары» булмаган шартларда вакыйгалар республикалар һәм өлкәләрнең фактта суверенлашу юлыннан китүен күрсәтерләр, бер үк вакытта яңа сәяси үзәкләр хасил булып, алар тирәсендә яңа союзлар оеша башлар.

IV БАШЛАМ

## Халыкларның үзбилгеләнүе һәм территориаль бөтенлек: халыкара хокук коллизияләре

Халыкара җәмгыять дөньяны дәүләтләрдән тора дип тәкрарлый, хәлбуки дөнья халыклардан тора. Бөек патшалыкларның лидерлары, дөнья тәртибен һәм сәяси процессларны без урнаштырабыз, дип уйлыйлар. Ләкин аларның бу тәкәббер уйлары халыкларның азатлыкка һәм үзбилгеләнүгә булган ихтыярына бәрелеп уала.

### *I. Татарстан һәм дөньядагы бүгенге тәртип*

Татарстан үзенең яшәп килүе белән дөнья җәмгыяте алдына күп кенә уңайсыз сораулар куя: Русия аның суверенлыгын танымагач, Татарстанны тануның кирәге бармы? Анклав территориядә принципта суверен дәүләт була аламы? Татарстанны халыкара җәмгыять таныса яки, киресенчә, танымаса, моның нәрсәгә китерүе мөмкин?

Көнбатышта сугыштан соңгы еллардагы пропаганда демократия өчен көрәш тамгасы астында барды. Шул лозунгка тиң рәвештә бөтен дөнья демократик һәм бидемократик илләргә аерылды.

АКШ конгрессы һәм БМО ел саен төрле илләрдәге режимнарның торышы турында нотыклар тыңлыйлар. Куәтле радиостанцияләр һәм көчле газеталар демократия стандартларына җавап бирми торган илләр исемлеген бөтен дөньяга тараталар. Шулай итеп җәмәгать фикере оеша, ә ул, демократияне яклау өчен дигән булып, хәтта сугыш игълан итүгә һәм астан таркату эшчәнлегенә, башка дәүләтләрнең эчке эшләренә тыкшынуга, сепаратчы көчләргә ярдәм итүгә һ.б. кадәр теләсә нинди хәрәкәтне акларга мөмкинлек бирә. Җир йөзендә Көнбатыш демократиясенең җиңүе хакына эшләмәстәй бернәрсә дә юк диярсең.

Татарстан бөтен демократик шартларны да үтәде. Игълан ителгән суверенитет гомумтанылган халыкара хокук нормаларына туры килеп кенә калмый, ул хәтта Русия кануннарына да каршы төшми; Татарстан Республикасы Президентын турыдан-туры һәм демократик сайлаулар булып узды. Бер үк вакытта Русия Президентын сайлаулар үткәрелмәде; референдум булып узды, анда халык үзе сайлаган юлга тугры икәнлеген раслады; ниһаять, Конституция кабул ителде, анда Республика демократик-суверен дәүләт халыкара хокук субъекты дип игълан ителде. Барлык сәяси процедуралар да Республикада чит ил күзәтүчеләре контрольлегендә барды, һәм алар демократик нормаларның аз гына булса да бозылуын сизмәделәр. Татарстанда теләсә нинди фиркаләр эш итә һәм төрле газеталар чыга, парламентта национал-радикаллардан алып Русия өчен бөтенесен бирергә җан атып торучы депутат төркемнәренә кадәр төрледән-төрле фракцияләр бар. Соң, алайса, ни өчен Татарстанны халыкара җәмгыять танып чыкмады? Бәлкем, республика андый танылу өчен соңгы шартны үтәмәгәндер — сугыш ачып җибәрмәгәндер?! Күрәсең, БМО халыклар сугыш телендә, хәрби шантаж яки деколонизация категорияләре белән сөйләшә башлагач кына алар авазына колак саладыр һәм хәрәкәт итә башлыйдыр, ә демократик тел әле аның көндәлек эш теленә әйләнмәгәндер?!

Гадәттә чит илләр экспертлары һәм сәясәтчеләре Татарстанга карата мондый сак булуны аны иң элек Русия танырга тиешлеге белән аңлаталар. Моның мәгънәсен аңлавы кыен түгел. Русия бит заманында бу җирләрне басып алган, алар — аның табышы. Шуннан Русиягә карап тормастан тану — бу, имеш, чит табышка кул сузу кебегрәк була...

Халыкара хокукый аң сугыш хәлендә булуның «табигыйлегеннән» чыгып эш итә. Бу кешелекнең бөтен узганыннан килеп чыга. Бүгенге дәүләтләр дә яңа җирләр яулап алу юлы белән яисә кулга корал алып азатлык өчен көрәш юлы белән барлыкка килгәннәр. Тегесендә дә, бу очракта да тупас көч уңышка ирешүнең соңгы һәм тугры чарасы булып килгән, ә сугышта җиңүче төп хаким булган. Шуның өчен Аурупа аңына, әйтик, Югославия халыкларының суверенитет өчен корал тотып көрәшүе дә, шулай ук сербларның үз дәүләтләре бөтенлеге өчен көрәше дә барып җитә. Ләкин Аурупага халыкларның тыныч юл белән үзбилгелә-

нүе, бигрәк тә халыкара оешмалар булышлыгы белән үзбилгеләнүе аңлашылмый. Әлегә хәрби фикерләү мантыйгы хакимлек итә, хәтта сәясәтчеләр тынычлык ягыннан торып көрәшкәндә дә.

Халыкара аренада демократия вакыт-вакыт гаҗәеп үзгәрешләргә дучар була һәм бик нык дәрәҗәдә конъюнктура сәяси мәнфәгатьләргә бәйле. Көнбатыш өчен, мәсәлән, Б.Ельцин фигурасы тылсым көченә ия диярсең, аңа терәк булу өчен Көнбатыш демократиясе күп нәрсәгә күз йомып калырга да риза. Әмма тагы да гаҗәбрәге Грузия белән бәйле. Аны тиз генә танып, БМОга да кабул иттеләр.

Ә бит Э.Шеварднадзе демократик юл белән сайланган, аннары көч белән бәреп төшерелгән Грузия Президенты урынына менеп утырды, Абхазиягә каршы сугыш ачты, абхазларны ачыктан-ачык кырып бетерергә чакырып торган парламентны җитәкли башлады. Сәер, ләкин факт — Э.Шеварднадзеның дуслык җепләре Көнбатыш илләре җитәкчеләренең демократик иманнарыннан көчлерәк булып чыкты. Алай гына да түгел, кеше хокукларын, хәтта аерым шәхесләрнең хокукларын бозу мәсьәләсендә бик вакчыл булган Берләшкән Милләтләр Оешмасы бүгенге көнгә кадәр Абхазиядәге сугышка карата үз позициясен белдергәне юк. Ә бит анда, асылда, тулы бер халыкның язмышы хәл ителә. Әхлак белән сәясәт бергә начар сыешалар, демократия лозунгысын сәясәтчеләр еш кына үзләренең дөнья белән идарә итү теләкләрен тормышка ашыру өчен файдаланалар.

Дөньяның дәүләтләр белән бүлгәләнгән икәнлеге мәгълүм әхвәлдер, шуңа күрә ул дәүләтләрнең үз мәнфәгатьләрен планета мәнфәгатьләреннән артыграк итеп күрә алмауларын аңлап була. Бөтендөнья сәясәтендә мәдәни һәм сәяси төрлелек бүгенге көндә яшәп килә торган дәүләт чикләрендә үз дәрәҗәләрен алган халыклар турында гына бара. Дәүләт чикләре — төп тамга. Шуның белән халык турында фикер йөртәләр, аның статусын билгелиләр һәм дөньяда аның торган урынын аерып куялар. Чик буйларың бар икән, сине таныйлар, алар юк икән, син халык түгел, син бары тик этнологлар игътибарына гына лаеклысың.

Берләшкән Милләтләр Оешмасы бик күркәм принциплар вә максатлар бәян итте. Ул исәптә гаделлек, тигез хокуклылык һәм халыкларның үзбилгеләнүе дә бар, әмма ләкин гамәлдә һәммәсе дә АКХК документларында ярылып ята торган дәүләтләрнең территория бөтенлеген саклауга кайтып калды. Үзбилгеләнүгә омтылган халык өчен үз-үзен танытырга бер генә юл кала — үз дәүләт чикләрен теләсә нинди чара белән булса да үзенә билгеләү. Үз капкаңны үзең яп (үз дәүләт чикләреңне үзең сыз) — хәзерге дөньядагы тәртип халыкларга шушындый шарт китереп куя.

Татарстан хәле һәм аның азатлыкка омтылышы тагын шуның белән дә катлаулана: ул анклавта калды, һәм аның башка дәүләтләр белән уртак чик сызыгы юк. Хәзерге карашлардан чыксаң, аның халыкара танылуына өмет итеп торасы да калмый.

Анклав проблемасы юристларга да, сәясәтчеләргә дә бик кыен хәл ителә торган мәсьәләгә әйләнеп бара шикелле. Ләкин мондый фикер аны хәрби проблема белән бергә бәйләп караганда гына туа ала. Чынлап та, хәрби тактика күзлегеннән караганда, анклавта калган халык бөтен яктан уратып алынган, аның кулын күтәреп дошманына бирелүдән башка юлы юк. Әмма ләкин шушы ук мәсьәләгә бөтенләй башка яктан да килеп карап булыр иде, ул — дөньяда иминлек саклау ягын күз уңында тоту. Алай иткәндә, максатның саны яңа дәрәҗәгә менә, һәм үзбилгеләнү процессына яңа фактор кушыла — анысы инде дөнья җәмәгате мәнфәгате була. Ул чакта инде «уратып алынган» хәлдә, тарихи үзгәрешләр аркасында йә булмаса басып алу сәбәбендә анклавта калган халыкларның теләген танымаучы дәүләт кала.

Сабыр фикернең «анклав» дигән төшенчә белән килешәсе килми. Имин көннәрдә дәүләт чикләре ачык була ала, килешүләр вә шартнамәләр кешеләрнең иректе йөрүен тәэмин итәләр. Димәк ки, анклав проблемасы — аны киңрәк итеп алганда, үзбилгеләнү мәсьәләсе — яңа сәяси фикерләү, тыныч вакытта бернинди хәрби (саклануы ул, яулап алуы) хәрәкәт белән бәйләнмәгән, тормыш итү өчен бик тә кирәкле булган яңача сәяси фикер йөртүгә кайтып кала.

Татарстан Республикасын тану-танымау Русиянең эчке проблемасы гына түгел, ул халыкара проблема. Татарстан мисалында без хәзер дөньядагы чишелеп бетмәгән мәсьәләләрнең бик киң балкышын күрәбез. Башка дәүләтләр тарафыннан Татарстанга мөнәсәбәт бер яктан территориаль бөтенлек принциплары кысасында тыпырчынучы халыкара хокук коллизияләренең бөтен катлаулылыгын күрсәтсә, икенче яктан ул халыкларның үзбилгеләнүгә хокукы барлыгын күрсәтә. Бик нык чияләнгән төен. Халыкара җәмгыять дөнья тоткасы дип халыкларны түгел, ә дәүләтләрне санаганда һәм дәүләтләр мәнфәгате дөнья мәнфәгатеннән өстенрәк дип исәпләгәндә, ул төен чишелмәс булып әверелә. Бу чуалчыкны чишү юлы хокукый сферадан битәр сәяси һәм хәтта фәлсәфи сферадан тора. Дөнья халкы сугыш фәлсәфәсеннән арынып үзара тыныч яшәү фәлсәфәсен беренче урынга куярга дучар. Татарстанга карата башка дәүләтләр тарафыннан мөнәсәбәт хәрби белән тыныч фикерләү арасындагы аерманың, алар арасында бара торган эчке көрәшнең нинди авыр, катлаулы, хәтта фаҗигале икәнлеген бик ачык күрсәтеп тора.

*II. АКХКнең «җимерелмәс ун сүрәсе» һәм Аурупаның бүгенге көне*

Берләшкән Милләтләр Оешмасы «халыкара тынычлык һәм куркынычсызлык» булдыру өчен урынлаштырылган иде. Аурупада куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек киңәшмәсенең (АКХК) Йомгаклау актында тынычлыкны саклау юллары ачык күрсәтелгән иде. Анда Аурупа илләре, шулай ук АКШ һәм Канада Үзара мөнәсәбәтләрдә монда катнашучы илләр эш итәчәк принциплар декларациясен кабул иттеләр. Анда ун принцип бар: «дәүләт чикләренең кагылгысызлыгы», «дәүләтләрнең территориаль бөтенлеге», «эчке эшләргә тыкшынмау», «көч кулланмау яисә көч куллану белән янамау» һ.б. Бу Декларация — «салкын сугыш» заманы; Аурупаның Совет басып алуыннан коты чыгып торган заманның бер сулышы иде. Үз заманында ул зур казаныш булды, чөнки сугыштан соң урнашкан чик буйларын канунлаштырып куйды, шуның белән Көнчыгыш агрессиясенең ихтималлыгыннан мәгълүм дәрәҗәдә иминлек тәэмин итте. АКХКнең ун сүрәсе, бушану чоры килеп җиткәч, аеруча СССРда үзгәртеп кору көннәре башлангач, үзләренең әүвәлге мәгънәсен югалттылар.

Ул шулай хәрби конфликтларны һәм дә хәрби тыкшынуларны бетерү максатын үз алдына куйган булгач, АКХКнең мотивларын аңлавы кыен түгелдер. Ләкин АКХК принциплары декларациясе нигезендәге ниятләр никадәр генә изге булмасын, барыбер аларның чикләнгәнлеген танымыйча булмый. Аерым алганда, үз дәүләтчелеге булмаган халыклар хокукларына нибары берничә юллык кына урын табылган: «Үз территорияләрендә азчылык милләтләр булган катнашучы дәүләтләр шундый азчылыкка караган кешеләрнең кануннар каршында тигезлеккә хаклары барлыгын ихтирам итәчәкләр, кеше хокукларыннан һәм төп азатлыклардан гамәлдә файдалануда тулы мөмкинлек бирәчәкләр һәм шул рәвешле бу өлкәдә аларның кануни мәнфәгатьләрен яклаячаклар». АКХК документларында БМО Уставы таныган халыкларның үзбилгеләнүгә хокукларына формаль генә булса да бер таяну юк. Соңгы еллардагы вакыйгалар, бу мәсьәләгә теоретик якын килүләрнең җитешсезлеген, халыкларның үзбилгеләнүгә хокукларын гамәлгә ашыруның барышын карап-тикшереп, моңа булышлык итәрлек иҗтимагый институтларның юклыгын раслады.

Дәүләт чикләренең кагылгысызлыгы принцибы беренче карашка бик камил булып күренсә дә, аны абсолютлаштырганда, тынычлык гаранты булудан этносара конфликтлар һәм сугышлар чыганагына әверелеп китәргә дә мөмкин. Чөнки ул гаделлек, тигезлек принцибы һәм халыкларның үзбилгеләнүгә хокуклары белән еш кына каршылыкка керә. Бу тезисны Югославиядәге хәлләр дә раслады. Андагы вакыйгалар Аурупадагы стабильлекнең бик чамалы икәнлеген күрсәттеләр. Халыкара җәмгыять, АКХКнең «изге сүрәләре»нә таянып эш итсә дә, көн саен Югославиядә сугышның киңәя баруын читтән генә борчылып күзәтеп торырга мәҗбүр булды. Ә сугыш эчендә этник «чистарту»лар бара, меңнәрчә кешеләр үлә, кешеләрнең ачуы чиктән ашып, алар озак еллар буена килешмәс дошманга әйләнәләр. Нәфрәт һәм бер-беренә ышанмау әүвәлге Югославия халыклары аңының аерылгысыз бер өлешенә әверелде, ә объектив рәвештә алар бер-беренә кирәк һәм бергә-бергә яшәүнең кулай вариантын таба алган булырлар иде. Моның өчен үз вакытында ук сербларның кызган башларына бераз салкын су кою да җиткән булыр иде, һәм Югославиянең бүленеше ул очракта Чехословакия юлы белән китә алган була иде. БМОның бу конфликтка катнашмыйча барыбер хәле юк иде, ләкин инде бу эш конфликтның бөтен Аурупага таралу куркынычы каршына килеп баскач, ә проблема үзе тәмам тупикка килеп кергәч кенә булды.

Югославия һәм СССРдагы этносара конфликтлар гомумаурупа килешүләренә караганда бик күпкә куәтлерәк булып чыктылар. Югославия Аурупаны яңа сугыш упкыны янына китереп бастырды. Шуның белән ул территориаль бөтенлек принцибын гына алга сөрүнең әле яңа сугышлар килеп чыгудан һич тә коткармаганлыгын күрсәтеп кенә калмады, алай итүнең халыкара җәмгыятькә зур зыян китерә алуын да раслады.

Юристлар территориаль бөтенлек принцибы белән халыкларның үзбилгеләнүгә хокуклары арасындагы коллизия хакында фикерләшәләр. Ләкин эш юридик формулировкалар эзләп табуга караганда күпкә җитдирәк тора. Абхазиядәге сугыш белән нишләргә? Анда бит бөтен бер халыкның җир йөзендә калу-калмавы хәл ителә. Хәзер нишләргә кала соң инде: АКХКнең «салкын сугыш» заманында ук эшләнгән принциплары хакына абхазларны кырып бетерергә ирек бирергәме?! Кайсы кадерлерәк: халыкның исән калуымы, әллә шул халыкны изеп тора торган дәүләтнең бөтенлегеме?!

Югославия аерым бер мисал булса да, бик тә гыйбрәтле үрнәк. Шуңа охшашлы проблемалар Русиядә, Бельгиядә, Испаниядә, Бөекбританиядә бар. Гыйракта, Төркиядә, Кытайда вакыт-вакыт бик кискен этносара конфликтлар чыккалап тора. Этносара нигездә менә күп еллар инде Индонезиядә сугыш бара. Һиндстанда һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиянең башка кайбер илләрендә сугыш хәрәкәтләренең туктап торганы юк.

Җир йөзендә биш меңләп этнос яши. Шуларның бары йөз сиксәне генә үз дәүләтләренә ия. Бу халыкларның күбесенең барлыгын да белүче юк, алар дөнья цивилизациясе үсешенең олы юлы читендә торып калганнар. Ләкин аларның дөнья югарылыкларына күтәрелергә омтылышларын туктата торган принцип-

ның булганы юк, аларның ireккә омтылышларын туктату мөмкин түгел. Ул табигый һәм изге омтылыш, ләкин ул бүгенге дөнья корылышының һәм тәртибенең ныклыгын әледән-әле сынап тора. Халыкларның үз азатлыклары өчен көрәше нәтиҗәсендә туа торган каршылыкларны чишү механизмы табылмый торып, дөньяның тыныч йокларга хакы юк.

Боларны дәүләтнең эчке проблемалары дип уйлау беркатлылык булыр иде. Бүгенге чикләрне ныклап урнаштыру һәм бер-береңнең эчке эшләренә тыкшынмау буенча әллә нинди декларацияләр кабул итәргә мөмкин. Әмма эчке процессларны тышкы дөньядан аеру һич мөмкин түгел. Бер-бер урында купкан этносара конфликтлар, кагыйдә буларак, бу көрәшкә теге яки бу халыкларны, йә этник, йә экономик якынлык аркасында яклый торган башка дәүләтләрне тартып кертәләр һәм территориаль бөтенлекнең бозылуына этәрәләр. Бәс, шулай икән, халыкларның үзбилгеләнүе буенча гомумтанылган процедуралар булдыру кулайрак булып чыкмыймы соң?!

Тайваньны яисә Төньяк Кипрны күрмәмешкә сабышырга мөмкиндер, ләкин алар бар бит, алар яшиләр. Шул ук рәвешле Татарстанны да танымаска мөмкин, ләкин аның үсеп бара торган йогынтысы сәяси ситуациядә чагылмый калмаячак. Төрле-төрле хокукый документларга таянып, азатлыкка сусаган йөзләрчә халыкларга күз йомып карарга мөмкиндер, ләкин табигый хокук башка теләсә нинди хокуктан өстенрәк тора һәм ул иртәме-соңмы хәтта иң аз санлы этнослар фикере белән санлашырга мәҗбүр итәчәк әле.

Халыкара җәмгыятьнең кайбер принципларының абсурдлыгын кеше хокуклары белән халыклар хокукларын яклауның икесен чагыштырып караганда ачык күрәсең. Хокук сакчысын, диссидентны эзәрлекләү башланса, бөтен дөнья матбугаты чаң сугарга тотына. Төрле-төрле җәмгыятьләр булдырыла, БМОда, АКШ конгрессында, Аурупа оешмаларында кайнар сүзләр тулы нотыклар сөйләнә. Ә инде халыкларның хокуклары турында сүз кузгалса, җәмәгатьчелек ул халыкларның акрынлап үлә баруына күрмәс күз белән гамьсез генә карап торуында була. Сахаров белән Буковскийларның исемнәрен ишетмәгән кеше калмагандыр, ә менә ингерманландлар яки кумыклар, шапсуглар яки нугайлар турында дөньяның аерым белгечләре генә ишеткәннәренә охшый. Русия җитәкчелеге Идел буе алманнарының дәүләт статусын, Германия кебек куәтле дәүләт басымына да карамастан, кире кайтарырга уйлап та карамый. Шуннан соң Аллаһы Тәгаләдән башка бер яклаучысы да булмаган башка халыкларга нишләргә кала соң инде?! Аларга, Кырым татарлары йә чеченнар кебек, үз хокукларын дәүләттән көрәшеп кире тартып алырга туры килә. Ләкин андый гамәлләр хәрби конфликтларга китерә. Кырым татарлары мәсьәләсе ничек хәл ителер? Үз орбитасына ул нинди илләрне суырып алыр? Осетиядә яки Абхазиядәге вакыйгалар ни белән бетәр? Төньяк Кавказда һәм Молдовада тынычлык урнашырмы? АКХКнең «ун изге сүрәсе»нең какшамаслыгын тагын бер тапкыр раслау өчен күпме кешенең җаны кирәк булыр икән?

Дәүләтләр status quoның саклануы хакына халыкларның хокуклары бозылуын да күрми калырга әзерләр, һәркайсы үз территориясе һәм үз чик буйлары турында гына уйлый. Англичаннар ирландлар белән шотландлардан сагаялар, канадалылар — Квебек кешеләреннән, испаннар — баскларда һәм каталоннардан һ.б. Status quoга таянырга һәркайсының үз сылтавы бар. Ләкин планетабызның уртак язмышы белән бербөтен буларак бәйләнгән бөтендөнья җәмгате мәнфәгатьләре дә бар бит әле. Аларны аерым дәүләтләр йә булмаса дәүләтләр төркеме мәнфәгатьләренә буйсындырып булмый. Халыкара хокукый аң, халыкларның санына һәм яшәү рәвешләренә карамастан, аларның хокукларының табигыйлегеннән чыгып фикер йөртергә тиеш. Дөньяның иминлеге инде сызылган чик буйларының ныклыгында түгел, ә бөтен халыкларга да үсешнең үзләре теләгән рәвешен сайлап алу мөмкинлеген булдыруга нигезләнгән.

### *III. Яңа халыкара мөнәсәбәтләргә таба хәрәкәт*

Арада иң демократиграк һәм ераккарак карап яши торган илләр милли азчылык һәм төп халыкларның хокукларын аныклый торган кануннар кабул итәләр. Аларның кайберләренең, мәсәлән, Дания белән Финляндиянең кануннамәләрен үрнәк кануннамә дип атарга була. Әмма ләкин хәтта барлык илләрдә дә шундый кануннар кабул ителгән очракта да халыкларның үзбилгеләнү проблемасы бетмәячәк, чөнки ул милли азчылыклар яки төп халыклар хәленә генә кайтып калмый, ә күптән-күп этносларга һәм территориаль берлекләргә дә кагыла. Бу — бөтендөнья җәмгыяте проблемасы, ул Халыклар хокукларының бөтендөнья декларациясен кабул итүне һәм тиешле халыкара оешмалар булдыруны таләп итә.

Төрле илләрнең моңарчы тупланган уңай һәм тискәре тәҗрибәсенә таянып, БМОның кеше хокуклары буенча комиссиясенең дискриминацияне булдырмау һәм азчылыкларны яклау буенча аскомиссиясе Төп халыклар хокукларының бөтендөнья декларациясе проектын әзерли. Анда күп кенә конкрет этник проблемалар истә тотылган. Хәлбуки документ үзе бөтендөньяви характерында булудан битәр «гамәли» рәвешендәрәк. Чөнки анда сүз аз санлы төп халыклар (Русиянең төньягындагы халыклар сыман) турында, кагыйдә

буларак, үзләренең традицион тормыш итү элементлары белән яшәүче һәм үз дәүләтләрен булдыруны дәгъва итмәүче халыклар турында бара. Бу проектта халыкара хокукның төп коллизиясе — территориаль бөтенлек белән халыкларның үзбилгеләнү хокукы арасындагы коллизия игътибарсыз калдырыла. Ә бу мәсьәләне хәл итә торган документның кирәклеге турында әйтеп тә торасы юк.

Бу проблеманың катлаулылыгы мәгълүм дәрәҗәдә хокук субъектының үзен билгеләү кыенлыгыннан килеп чыга. Кем үзбилгеләнүне дәгъва кыла ала да, кемне халык дип атарга? Бу уңайдан күп кенә сәясәтчеләр суверенлашу процессының чиге булмас дип сагаялар, чөнки принципта, әгәр дә аң белән фараз итсәң, теләсә нинди этник төркем, милли азчылык яисә территориаль берлек, үзен халык дип игълан итеп, үз дәүләтен кора башларга мөмкин. Бу вакытта ул табигый байлыкларын да, үз дәүләт чикләрен дә, таможня постларын булдыруны да дәгъва итә ала. Суверенлашуның чикләре бармы аның?

Теоретик яктан, халыкларның үзбилгеләнүе юлына чикләр кую мөмкин түгел — каты критерийлар булсын өчен ни сан ягыннан, ни башка яктан характеристикалар юк. Ләкин реаль сәяси һәм икътисади практика бар. Кешеләрнең көнкүреше бик күп кысалар белән чикләнгән булуы ачык нәрсә: монда географик территория дә, экологик даирә дә, табигый ресурслар да, тел даирәсе дә, мәдәни берлек тә, үткәндәге тарих та, гүзәл да һ.б. да керә. Реаль практика җәмгыятьнең чиксез атомлашуы (бүленеше) юлына шактый каты шартлар куя, һәм процесс кешеләрне берләштерә торган күп факторлар аркасында детерминлашкан булып чыга. Халык ул — үзбилгеләнүгә омтылышын ачык белдергән кешеләрнең социаль берлеге, һәм аның мөстәкыйль субъект буларак шушы халыкның мәнфәгатьләрен гәүдәләндерүче иҗтимагый һәм дәүләт структуралары була.

Бу төшенчә этник билгеләр белән тулысынча туры тәңгәл килеп бетми, күп яктан ул төп халык төшенчәсенә турырак килә. Хәлбуки тормышта бер халык сыйфатында бер генә түгел, берничә этнос яисә төрле тарихи яки башка сәбәпләр аркасында төп массивыннан аерылган зур этносның бер өлеше чыгарга мөмкин. Тарихның мөстәкыйль субъекты буларак чыгарга сәләтле халыклар исемлеген алдан ук билгеләү шактый катлаулы. Моның өчен әле этник характеристикалардан тыш сәяси практиканы исәпкә алу әһәмиятле. Ахыр чиктә теге яки бу берлекнең үзбилгеләнүгә дәгъваларының реаль дәрәҗәсен әнә шул билгели.

Нигә соң әле безгә БМОның халык хокукларын яклый торган махсус документы кирәк булды? Һәрбер кеше бөтен хокуклар һәм ирекләргә ия булырга тиеш дип игълан ителгән Кеше хокукларының бөтендөнья декларациясе җитмәгәнмени? Анда бит кешеләр расасына, тән төсенә, җенесенә, теленә, диненә, сәяси һәм башка иманнарына, милли яки социаль чыгышына карамастан, мөлкәте, катламы яисә башка хәле ягыннан бертигез дип карала. Чынлап та этник тигез хокуклылык игълан ителгәч, тел һәм башка яклардан эзәрлекләү тыела, геноцидка һәм этноцидка каршы БМОның махсус документлары бар. Әмма алар бу нормаларның үтәлешен гарантияли торган тиешле институтлар белән ныгытылмаган.

Милли дәүләтләрнең, этносларның, аеруча күпсанлы һәм үз-үзен тотышында бәйсез булган этносларның үсешен бик кайгыртып торасы килми. Алар андыйларда территориаль бөтенлекләренә куркыныч күрәләр. Мисал өчен Русияне генә алыйк. Монда урыс булмаган халыклар, асылда, үз туган телләрен чит тел өйрәнгән кебек өйрәнәләр, мәдәниятләрен үстерергә акча аз бүленә, мөстәкыйль рәвештә табигый ресурсларыннан файдалана алмыйлар, фактта алар Мәскәүнең ярымколонияләре. Федераль хөкүмәт моңа риза, ә халыкара җәмгыятьнең моңа исе китми. Киресенчә, мондый проблемаларны уртага салып тикшерү халыкара җәмгыять тарафыннан дәүләтләрнең эчке эшләренә оятсызларча тыкшыну дип кабул ителә. Шуның белән кеше хокукларын бозуларга ләббәйкә укыла. Алай гына да түгел, Русия Федерациясе республикаларының дәүләт суверенитеты турында декларацияләр игълан итүләрен дөнья матбугаты коммунистик көчләрнең Б.Ельцин йөзендәге демократиягә каршы чыгышы дип тамгаларга базды. Экс-автономияләрнең хәрәкәт мотивларын аңлыйсы урында аларга төрле ярлыклар тактылар. Аның урынына дөнья җәмәгатьчелеге рәхәтләнеп, Русия сәясәтчеләре ыргытканны кабып, Эстониядә, Латвиядә һәм Литвада «урысларның хокукларын бозу» турында чүбек чәйни. Ә монда бит урысларның туган телләрендә белем алырга, урыс газеталары укырга, Русия телетапшыруларын карарга бөтен мөмкинлекләре бар — алардан бары бу илләр кешеләре белән иркен аралашу өчен берничә эстон, латыш, литва гыйбарәсен өйрәнү генә таләп ителә. Дөньяда бөтенесе дә олуг патшалыклар кулына кереп беткәч, алар, демократия лозунгларына сыенып, халыклар язмышын хәл итәләр.

Күрәсең, җирдә тынычлыкны саклау хакына халыкларны дискриминацияләүне туктатуның әһәмияте хакында тагын бер кат искә төшереп китүнең зыяны булмастыр. Аның әһәмияте кеше хокукларын бозуны туктатудан ким түгел. Сугышлар һәм революцияләр килеп чыгу сәбәпләрен тикшерә башласаң, этносара конфликтлар, мөгаен, беренче урынга чыгарлар иде әле. Һәрхәлдә, бу күңелсез статистикада аның өлеше, конфликт сәбәбе буларак, кеше хокукларын бозуга караганда күпкә берәгәйлерәк.

Халыклар хокукларының бөтендөнья декларациясе нигезенә шактый принциплар салынырга тиешле. Иң әүвәл кеше хокукларын халыклар хокукларыннан аерып карарга ярамый, чөнки һәр кешенең үз хасият-

ләре була: ул телдә, мәдәнияттә күренә, кеше үз милләте йолаларына һәм гадәтләренә ия һ.б. Бу ихтыяҗларны канәгатьләндерүне кеше хокукларын тәэмин итүнең аерылгысыз өлеше итеп карау кирәк.

Кеше хокуклары халыклар хокукларына зыянга файдаланылырга тиеш түгел. Кануннар, хәтта алар кеше хокукларын яклау хакына дип кабул ителсәләр дә, әгәр дә алар халыкларның сәяси, икътисади, социаль һәм мәдәни үсешләре мәнфәгатенә каршы килә икән, андый кануннар гуманлы дип исәпләнә алмыйлар. Кеше хокуклары белән халыклар хокукларының ярашуы принцибы Декларациянең нигезенә ятарга тиеш.

Демократик лозунглар еш кына үзбилгеләнү идеяләрен дискредитацияләү һәм хәтта сәяси хәрәкәтләрне һәм фиркаләрне бастыру өчен дә фйдаланыла. Демократияне еш кына шактый примитив аңлыйлар. Имештер, ул — монда торучыларның күпчелегенең генә фикерен ачыклау, этник азчылыкларның мәнфәгатьләрен исәпләп тормасаң да була, янәсе, һ.б. Ә бит демократиянең тәүге мәгънәсе — халык хакимлеге дигән сүз. «Монда торучылар» түгел, ә «халык» категориясе аның асыл характеристикасы булып тора. Демократия абсолют кыйммәт түгел, ул халык мәнфәгатьләре белән бергә бәйләнгәндә генә үз мәгънәсен ала, һәм шуңа күрә демократик процедуралар этносларның хокукларын кысарга нигез була алмыйлар һәм булырга тиеш тә түгелләр. Моннан түбәндәге нәтиҗә килеп чыга: этносларның үсешләрен тәэмин итмәүче, ә аларның хокукларын кысучы дәүләт бигрәк тә инде демократик дәүләт дип санала алмый.

Үзбилгеләнү хокукы үз дәүләтеңне булдыру мөмкинлеген күз алдында тота. Бу хокукны башкача аңлату аның мәгънәсен суырып ала, чөнки азатлыкның мәгънәсе дә шуннан тора бит инде: халык үз язмышын үзе хәл итәргә, сәяси һәм икътисади тормышын мөстәкыйль рәвештә үзе корырга тиеш. Халыкның үз дәүләтен булдыру хокукы бары тик шушы халыкның гына шик калдырмаслык итеп һәм демократик юл белән белдерелгән үз ихтыяры аша гына чикләнергә мөмкин. Шуңа күрә бернинди халыкара документ та халыкларның үзбилгеләнүгә хокукларын чикли ала дип карала алмый. Бу уңайдан чикләрнең кагылгысызлыгы һәм территориаль бөтенлек принцибы үзбилгеләнүгә омтылучы халыкны көчләп тотып торуга аклану булып хезмәт итәргә тиеш түгел.

Һәрбер халыкның, үз дәүләтен төзиме ул, юкмы, үз территориясенә хакы бар. Бу этносларны саклауның бик тә әһәмиятле шарты, һәм аны бозарга мөмкинлек бирә торган бернинди сәбәп тә юк. Кәсәбәчелек иреге дә, дәүләт иминлеген тәэмин итү һәм җиргә хосусый милек хокукларында дәүләтнең нинди дә булса «олуг мәнфәгатьләре» дә — бернинди сәбәп тә моның өчен кулланыла алмый. Халыкның яшәү һәм үсеш шартларын чикләргә беркемнең дә хакы юк. Үз территориясендәге табигый байлыкларны ничек һәм кем мәнфәгатендә эшкәртү яки бөтенләй эшкәртмәү кирәклеген бары ул үзе генә хәл итә ала. Дәүләт суверенитетының теге яки бу халыкның көн күрмеш шартларын тәэмин итә торган нәрсәләргә кагылышы юк.

Төрле әхвәлләр аркасында халыклар үсешнең төрле баскычларында булып чыктылар, һәм аларның үз кулларында дәүләт дигән шундый куәтле корал булганнары «дәүләтсез» халыклар белән чагыштырганда тагын да зуррак өстенлекләргә ия булалар. Күп халыкларның артталыгы (ә моны рәсми хакимиятләр еш кына аларның үзбилгеләнү хокукларын чикләгәндә аргумент итеп файдаланалар) күп яктан тарихи гаделсезлек, үткәндә басып алыну белән аңлатыла. Халыкларны дискриминацияләвен аларның артталыгына сылтарга тырышучы дәүләт үзе үк шушы артталыкның сәбәпчесе булып чыга. Шуңа күрә мондый халыкара принципны расларга кирәк: аның буенча теге яки бу халыкны изеп килгән дәүләт ул халыкның алдагы үсеше өчен матди һәм әхлакый җавап тотарга тиеш була. Шулай итмәгәндә, төрле халыкларның үсеш дәрәҗәләрендәге аерма һаман арта гына барачак, һәм неоколониализм, интеллектуаль, гыйльми, профессиональ һәм башка төр өстенлекләрдән файдаланып, яңа, тагы да астыртынрак рәвешләргә керәчәк.

Геноцид һәм этноцидка дучар ителгән халыкларның хокукларын кире кайтару процедурасы хакында аерым әйтеп үтәргә кирәк. Тормыш дәүләтләрнең ул хокукларны торгызырга ашкынып тормауларын күрсәтә. Моның ачык мисалларын без Кырым татарлары һәм әүвәлге СССРның туган җирләреннән сөрелгән башка халыклары үрнәгендә ачык күрәбез. Турыдан-туры халыкара контроль булмый торып, ул хокукларның торгызылу ихтималы бик аз.

БМОның да, АКХКнең дә, кызганычка каршы, халыкларның үзбилгеләнүе процедурасын билгеләрлек һәм этносара конфликтларны кисәтерлек эшләнгән чаралары һәм тиешле институтлары юк. Халыкларның хокукларын билгели торган халыкара документлар кабул итү ул әле яңа типтагы халыкара мөнәсәбәтләрне формалаштыруда беренче адым гына. Халыкларга декларацияләр генә түгел, ә гомумтанылган нормаларны тормышка ашыру өчен дәүләтләр һәм халыкара җәмгыять тарафыннан бирелергә тиешле гарантияләр дә кирәк.

Бу юлда иң радикаль практик адым булып БМОның икенче палатасын иганә итү (урынлаштыру) тора алыр иде. Ул палата дәүләт вәкилләреннән түгел, ә демократик юл белән сайланган делегатлар йөзендә халыклар вәкилләреннән торыр иде. Халыклар турыдан-туры үз хәлләре һәм ниятләре турында чыгып дөресен сөйли алырлык андый палатаны булдыру күп кенә бозулар һәм этносара конфликтлардан котылып ка-

лырга мөмкинлек бирер иде. БМОны яңа принципларда үзгәртеп кору халыкара җәмгыятьне тупиктан чыгарыр һәм аңа яңа перспективалар ачар иде.

Җирдә тынычлыкны саклау өчен, шулай ук Халыкара хөкемгә халыклар хокукларын бозулар турындагы эшләрне карау һәм шулай ук теге яки бу халыкның үзбилгеләнүе турындагы мәсьәләне куярга хакы бармы-юкмы икәнлеге турында карар чыгару хокукын бирү дә бик файдалы булыр иде. Үзбилгеләнү процедурасын халыкара оешмаларның контроле астында алып бару этносара һәм территориаль конфликтларны йомшартырга ярдәм итәр иде.

Берләшкән Милләтләр Оешмасы үзенең Уставында гаять әһәмиятле принцип буларак халыкларның үзбилгеләнү хокукын раслап куйган иде. Үткән вакыт эчендә бу хокук декларация генә булып кала бирде, аны тормышка ашыра торган тиешле нормалар һәм халыкара механизмнар белән ул ныгытылып куелмады. БМО, асылда, дәүләтләр арасындагы чикләрне ныгыту белән шөгыльләнде. Вексельләр өчен түләр вакыт та килеп җитте шикелле инде. Халыклар көтә.

## Йомгак

XX гасыр тәмамланып килә. Аның эчендә ике бөтендөнья сугышы булып узды, дөнья колониаль системасы таркалды, олуг империяләр җимерелде. Империяләрнең соңгысы — Русия империясе — тирән кризис кичерә, үз кысасыннан яңа дәүләтләр бүлеп чыгарырга әзерләнә.

Кешелек тарихы башыннан алып бүгенге көнгә кадәр халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрдә сугыш фәлсәфәсе өстенлек алып килде. Дөньяның тоткасы булып көч тора, һәм ул бөек мәмләкәтләр тарафыннан идарә ителә. Хәлбуки «киеренкелекне киметү» кешеләрнең һәм сәяси лидерларның аңын үзгәртә башлады. Халыкара мөнәсәбәтләрне каты үзгәрешләр чорнап алды. Тынычлык фәлсәфәсенә нигезләнгән яңа эпоха килә, һәм ул үзе белән тарих мәйданына моңарчы аз билгеле булган халыкларны да алып чыга.

Кешелек каршына җавап бирелергә тиешле сорау килеп басты: җир йөзендә тынычлыкны саклау өчен, планетаның чәчәк атуы һәм кешелекнең киләчәге өчен кайсысы әһәмиятлерәк: халыкара җәмгыятьнең болай да көчле һәм мәкерле булган дәүләтләргә терәк булуымы, әллә дөнья цивилизациясенә йөз тоткан халыкларны яклаумы? Бу сорау, әгәр дә сәяси мәсьәләләрне хәл иткәндә дәүләтчелеккә таянып киленмәгән булса, риторик сорау гына булып күренер иде.

Дәүләтләр гаять зур көчкә һәм чикләнмәгән диярлек хакимлеккә ия. Алар ихтыярына каршы торырлык көч юктыр да шикелле, бигрәк тә инде «дәүләтсез» халыкларның шансы юк кебек. Әмма ләкин планетар мәнфәгать бар бит әле: ул үз җаныңны саклау хисеннән килеп туа һәм дәүләт мәнфәгатьләреннән өстенрәк тора. Үз заманында БМО колонияләрдәге халыкларны яклап чыккан һәм дәүләтләрне империализмнан арынырга мәҗбүр иткән иде. Бүген икенче «деколонизация» дәвере башланып килә. Планетабызның күмәк акылы халыклар хокукларын яклау һәм җир йөзендә уртак тынычлык хакына тәкәббер патшалыктан өскәрәк күтәрелә алмый калмас. Моңа аның сәләте дә, көче дә җитәрлек...

# ТАТАРСТАН КАЯ ЧЫГА?

## Кайсы мөһимрәк — халыкның яшәвеме, әллә дәүләтнең бөтенлегеме?

атарстан ахыр чиктә Русиядән чыгамы-юкмы инде? Бу сорау торган саен бәйләнчек идеягә әверелә бара һәм кайберәүләрнең ачуын да кабарта.

Русия дәүләтенең аякка басуы 1552 елда Явыз Иван Казанны яулап алгач башланды. Русиянең бүгенге җитәкчелеге меңьеллык державаның таркалуы да Казаннан башланудан курка. Борчылыр өчен сәбәпләр бар, ләкин алар Казанныкында түгел, ә Мәскәү Кремлендә яшеренеп ята.

Демократлаштыру «бердәм һәм бүленмәс» Русиянең легитимлыгын (законлы булуын) җимерде. Һәм шуңа күрә кушып булмый торган нәрсәләрне укмаштырырга маташу файдасыз: халык хакимияте яки бөекдержавачылык сайларга туры киләчәк.

Татарстан хакында нәрсә генә сөйләмәсеннәр, ләкин референдумда күпчелек суверенлык өчен тавыш бирде, ә «каршылар» аның йомгакларын таныдылар. Сәяси акт гамәлгә ашты. Иң мөһиме, Татарстанда, теленә, чыгышына, мәдәниятенә карамастан, халыкның барчасы үзбилгеләнә. Референдум йомгаклары белән килешмәскә һәм аны фәкать «социологик сораштыру» дип кенә атарга да мөмкин, билгеле, ләкин бу очракта тормыш үз юлы белән китсә, үпкәләргә кирәкми.

Русиянең территориаль бөтенлеге әлеге тарихи традиция, дөресрәге, инерция буенча саклана. Аның хокукый нигезе терәүләргә тотынып кына тора. Федератив килешү «өстә» төзелде, һәм шуңа күрә ул, җәмгыять демократияләшә барган саен, даими рәвештә җимерелә тора. Татарстан башлап йөрүче түгел, ә бу процессның индикаторы гына. Чиратта — Якутия, Тува, Ерак Көнчыгыш, Себер, эре өлкәләр... Бөекдержавачыл Русия белән «сугышны» Татарстан түгел, ә демократия принциплары алып бара...

Базарга күчкәч, Җир шарының алтыдан бер өлеше белән үзәктән торып идарә итәргә мөмкин дип уйлау — сабыйлык. Мәсәлән, Калининград өлкәсе белән Камчатка арасында чынбарлыкта нинди икътисади бәйләнешләр яши алсын ди. Аларны салым җыючы федераль органнарның мәнфәгате бәйли. Бер мәйданда шулкадәр күптөрле территорияләрне, мәдәниятләрне, халыкларны фәкать көч ярдәмендә генә тотып торырга мөмкин. Ә базар аларны тегендә-монда йолыккаячак. Шул чакта Мәскәүдән дә көчлерәк тарту көченә ия үзәкләр барлыкка киләчәк. Җирле чимал чыганаклары, Германиягә, Финляндиягә, Кытайга якын булу һәм башка факторлар шуңа этәрәчәк. Ә Федератив килешү өлкәләрне суверенлаштыру һәм аларны республикаларга әверелдерү өчен юридик нигез булып хезмәт итәчәк.

Шунысын да әйтеп китәргә кирәк, ягулыкка һәм моңа бәйле рәвештә юл чыгымнарына бәяләр күтәрелгәннән соң, элемтәне, коммуникацияләрне һәм Русия белән идарә итүне оештыру техник яктан да үтә кыен булачак. Ягулык бәяләренең бәйдән ычкынуы үзәктән качу гамәлләренә Татарстан сәясәтенә караганда ныграк йогынты ясаячак.

Русиянең «төбәкләргә» аерылу процессы дөньяда бара торган гомуми агымга һич тә каршы килми. АКШ һәм СССР кебек ике бөек держава арасындагы дошманлыкка чик куелгач, Канадада, ГФРда, АКШта, Бөекбританиядә, Бельгиядә, Испаниядә, Төркиядә һәм башка илләрдә эчке элемтәләр йомшарды. АКШ штатлары арасында һәм ГФР җирләренең федераль хөкүмәтләр белән бәйләнешләре проблемасы туды. Әгәр Канада таркалса, бу хәл Төньяк Америка континентында бөтен картаның үзгәрүенә китерәчәк.

Халыкара җәмәгатьчелек, дөнья дәүләтләрдән тора, дип, үзен-үзе алдап яши. Чынлыкта, ул халыклардан тора.

Югославия һәм СССРдагы милләтара низаглар чикләр һәм территорияләрнең какшамаслыгы принцибына нигезләнгән Европа иминлегенең салам аякларда гына торуын күрсәттеләр. Халыкара җәмәгатьчелек өчен нindидер бер «илаһи канунга» әверелгән Европа Бердәмлеге декларациясендәге «ун кагыйдәгә» сукырларча иярү Европаны яңа сугыш чигенә китереп терәде. Халыкларның үзбилгеләнү хокукын гамәлгә ашыруның тәртибен ачыклау өчен БМОның һәм АКХКнең килешенгән концепцияләре дә, тиешле институтлары да юк. Нәкъ менә шуңа күрә Кавказдагы һәм Югославиядәге бәрелешләр алдында алар чарасыз калдылар да. Ә сербларны низаг башлангач ук туктатырга һәм мәсьәләне Чехословакиядәге кебек хәл итәргә мөмкин иде.

Юристлар территориаль бөтенлек принцибы һәм халыкларның үзбилгеләнүгә хокукы арасындагы каршылыклар хакында акыл саталар. Ләкин эш монда юридик билгеләмә эзләүгә караганда күпкә җитди. Мисал өчен Абхазиядә барган сугышны алыйк. Анда бөтен бер халыкның яшәү-яшәмәве мәсьәләсе куела. Нәрсә, хәзер «салкын сугыш» чорында эшләнгән Европа Бердәмлеге принциплары өстенлек итсен дип абхазларны кырып бетерү мөмкинлеге бирергәме? Кешелек дөньясы гади бер сорауга җавап бирергә тиеш: нәрсә мөһимрәк — халыкның яшәвеме яисә шушы халыкны изгән дәүләтнең бөтенлегеме?!

Мондый конфликтларны хәл итү өчен халыкара механизмнарның булмавы аркасында күрәшкә теге яки бу халыкны якынрак күргән күрше дәүләтләр дә катнашып китә. Ә бу исә дөньяның иминлеген кыл өстенә куя.

Югославия, СССР — бу әле башы гына. Шундый ук проблемалар Испаниядә, Бельгиядә һәм Бөекбританиядә яшәп килә. Төркиядә һәм Гыйракта — көрдләр, Кытайда тибетлылар һәм төркиләр мәсьәләсе хәл ителмәгән. Индонезия, Һиндстан һәм башка илләрдә дә кискен милли каршылыклар җайга салынмаган. Җир шарында 5000 гә якын этнос яши һәм аларның фәкать 180 е генә халыкара танылган дәүләтчелеккә ия. Халыклар сортларга бүленгән һәм бу гадел түгел.

Кеше хокуклары һәм халыкларның хокуклары һич тә тигез якланмый. Дөнья җәмәгатьчелеге өстенлекне һәрдаим кеше хокукларына биреп килә.

Үз статусларын саклап калу өчен дәүләтләр халыкларның хокукларын бозуны күрмәмешкә салышалар. Һәркайсы үзенең территориясе һәм чикләре хакында уйлый. Лондон ирландлылардан һәм шотландлылардан шикләнә. Оттава — Квебек халкыннан, Мадрид басклар һәм каталоннардан курка. Дөньяда шушы тәртипне саклап калу өчен аларның һәрберсендә сәбәп бар. Бу хәл исә Җир шарында тотрыклы иминлек урнаштыруга комачаулык итә. БМО боларның барысына да күз йома. Җәмәгатьчелек дәшми.

Дөнья җәмәгатьчелеге халыкларның хокукларын яклау һәм Җир шарында тотрыклы иминлек урнаштыру хакына державачылык идеясеннән баш тарта алыр иде. Моның өчен зирәк акыл һәм планета мәнфәгатьләрен алга сөрү кирәк. Үз вакытында БМО, колониаль халыкларны яклап чыгып, дәүләтләрне империа-

лизмнан баш тартырга этәрә алды бит. Бүген «колонияләрне юк итүнең» икенче чоры башлана. Бу юлда Халыкларның хокуклары декларациясе беренче адым булыр иде, чөнки аңардан башка Кеше хокукларының гомуми декларациясе тиешле дәрәҗәдә хезмәт итә алмаячак. Үз дәүләтчелегеннән мәхрүм халыклар өчен БМОның икенче палатасын төзү бу юнәлештә икенче хәлиткеч адым булачак. Өченче адым — халыкларның хокукларын бозу турында эшләрне карау өчен Халыкара судка хокуклар бирү.

Иң мөһим принцип сыйфатында БМО халыкларның үзбилгеләнү хокукын теркәде. Аны тиешле нормалар һәм механизмнар белән ныгытыр вакыт җитте. Шул чакта БМО эшчәнлеге өчен яңа офыклар ачылачак.

Татарстан кая чыга соң? Халыкара мәйданга чыга. Моның өчен аны хөкем итәргә һәм аңа каршы көч кулланырга кирәкме?! Татарстан нәрсәне җимерә? Ул мөнәсәбәтләрдә империя структураларын, колониаль үткәннең калдыкларын җимерә. Моның өчен аны хурларга кирәкме? Татарстан Русиягә тигез хокуклы һәм гадел шартларда килешү төзергә һәм шуның белән традицион элемтәләрне саклап калырга һәм ныгытырга тәкъдим итә! Ул үзара аңлашу һәм милли мәсьәләне хәл итүдә имин юл тәкъдим итә. Моның өчен хөкем итәләрмени?!

## СУВЕРЕНИТЕТ КЕМГӘ КОМАЧАУЛЫЙ?

усиянең Милләтләр һәм федерация эшләре буенча дәүләт комитеты һәм татарларның Бөтендөнья конгрессы башкарма комитеты канаты астында Яшел Үзәндә Русия төркиләренең үсеше мәсьәләләренә багышланган киңәшмә-семинар булып узды. Бу яңа ведомство оештырган чараларның беренчесе генә түгел. Әмма федераль хөкүмәтнең әле дә булса милли сәясәт кануннарын эшли алганы юк. Шуңа күрә әлеге сәясәт, кызганычка каршы, нигездә, конференцияләр һәм киңәшмәләр үткәрүгә генә кайтып кала, бирегә халык нәрсә белән килсә, шуның белән кайтып китә һәм чишеләсе мәсьәләләрне өйләрендә үз белдеге белән хәл итәргә мәҗбүр була.

Татарстан җитәкчелеге, шулай ук башка республикаларның башлыклары Русиядә милли сәясәтне җайга салу мәсьәләләрен күп тапкырлар күтәреп чыктылар, әмма федераль хөкүмәт әлеге мәсьәләгә һаман да бармак аша карый. Милли сәясәт концепциясе юк. Русия халыклары мәдәниятен үстерү программасы юк, милли азчылык турында да, милли-мәдәни автономия турында да кануннар юк. Аның каравы күпмилләтле Русия турында сүз куерталар һәм үзара тату яшәргә чакырулар хәттин ашкан.

Әгәр Русия чын мәгънәсендә федератив дәүләткә әверелсә, бу, әлбәттә, милли мәсьәлә иң муафыйк чишелеш тапты дигән сүз булыр иде. Ләкин бүген Мәскәү «федерация» дигән төшенчәнең төп мәгънәсен субъектларның хокукларын яклау дип түгел, ә киресенчә, үзәкнең чикләнмәгән хокукларын «тәгәрмәчкә таяк тыгучы» субъектлардан саклау дип аңлый.

«Дөньяда мисалы булмаган аерым статус» дәгъвалаучы Татарстанның эзлекле һәм тайпылышсыз кыйбласы инде күптән Мәскәүнең эчен пошыра, һәм ул бу, янәсе, Русияне таркатуга алып бара дип борчыла. Ләкин бит хәтта АКШ яки Германия кебек классик федерацияләрдә дә «аерым» статуслы субъектлар бар. Мәсәлән, Луизиана штатының АКШтан чыгу хокукы бар, һәм ул, әгәр теләсә, федераль органнардан фатиха сорап та тормый. Бавария ирекле дәүләт дип атала, ә күптән түгел Саксония дә үзен шундый дәүләт дип игълан итте. Ләкин моңа карап берәү дә АКШны яки Германияне таркаталар дип чаң сукмый һәм беркем дә субъектларның хокукларын тигезләү мәсьәләсен кузгатмый.

Әгәр Татарстан позициясенә дөнья тәҗрибәсе күзлегеннән карасак, аның һич тә «особый» булмавын күрербез. Татарстан Республикасының 61 нче маддәсе республиканы Русия белән ике яклы килешү нигезендә ассоциацияләшкән суверен дәүләт дип игълан итә. Мондый мөнәсәбәтләрнең гайре табигый нәрсә булмавын АКШ мисалында тагын бер тапкыр күрәбез. Мисал өчен, 1975 елда бу ил «Кушма Штатлар белән Пуэрто-Рико арасында озак сроклы союз турында» закон кабул итте. Закон ирекле рәвештә ассоциацияләшкән дәүләт буларак Пуэрто-Риконың статусын таныды. Пуэрто-Риконың үз Конституциясе, үз гражданлыгы бар, һәм АКШ конгрессына сайлауларны ул үз законнары буенча үткәрә. АКШ чын мәгънәсендә бөек һәм демократик держава буларак Пуэрто-Рико халкы ихтыяры белән исәпләшә һәм теге яки бу ысулны кулланып аңа нинди дә булса йогынты ясау турында уйламый.

Федератив төзелешнең мәгънәсе субъектларның хокукларын кысуда түгел, ә киресенчә, федераль хөкүмәтнең хакимиятен чикләүдә. Бу хөкүмәт уртак яшәешне тәэмин иткән функцияләр (оборона, чикләрне саклау, гомуми финанс системасын оештыру, тышкы политика) белән генә шөгыльләнә. Шушылардан калган эшләрнең барысы да субъектларның вазифасы һәм федераль хөкүмәт бу эшләргә бернинди изге сылтау белән дә тыкшынырга тиеш түгел. Тагын шунысын да әйтик: федератив дәүләтләрдә беркем дә субъектларның хокукларын тигезләү белән шөгыльләнми. Бу махсус уйлап чыгарылган проблема, аны җәмгать-

челек фикерен төп мәсьәләдән мәңге туя белмәс Үзәкнең зур аппетитын бераз чикләү мәсьәләсеннән читкә юнәлтү өчен юри китереп тыктылар.

Русиянең яңа Конституциясе проекты «без Русиянең күпмилләтле халкы» дип ярыйсы гына башланып китә. Әмма текстның калган өлеше тулысы белән бу тезиска каршы килә. Русия унитар дәүләт Конституциясе кабул итәргә җыена. Анда халыкларга да, милли азчылыкларга да бернинди гарантияләр каралмаган. Налог, бюджет һәм финанс системасы чын мәгънәсендә унитар дәүләтнеке. Суверенлык турындагы маддә алып ташланган, Федератив килешү кирәксез кәгазь төсле алып ыргытылган, республикалар гражданлыгы сызып ташланган, Екатеринбургның республикалар белән тигезләнергә беркатлы омтылышы тамырыннан киселгән. Мәскәү гомер буе Русия халыкларыннан, шул исәптән урыс халкыннан да курыкты. Үзәкнең Урал республикасын танымавы — аңы уянган урыс халкыннан курку ул.

Күпләр Б.Ельцинның Казанга килгәч әйткән «Суверенлыкны йота алган кадәр алыгыз» дигән сүзләрен әле дә хәтерлиләрдер, әмма аның тулаем федератив төзелеш турындагы фикерләрен хәтерләүчеләр бармы икән? «Ленинец» газетасына биргән интервьюда ул менә болай дигән иде: «Иң беренче урынга милләтләрнең мәнфәгатьләрен куярга кирәк, чөнки алар өчен федерациягә керү милләткә яхшы булганда гына файдалы. ...Федерация... республикалар суверен булганда, үзләренең милли байлыкларына үзләре хуҗа булганда гына көчле була ала». Моңа өстәп, сәяси эшлеклеләр үз сүзләренә хуҗа була белгәндә дә начар булмас иде дип әйтәсе килә.

РФ Конституциясен яклаучыларның күбесе, анда кеше хокуклары турында шәп язылган, диләр. Формаль яктан караганда, «сталин», «брежнев» конституцияләре дә шәп язылган иде, әмма аларда республикалар, халыклар һәм кеше хокукларын яклауны тормышка ашыру механизмы юк иде шул. Моны без «ельцин» конституциясендә дә күрмибез. Әле алай гына да түгел, аны кабул иткәннән соң, Русиядә авторитар режим башланачак, чөнки президент кулына дәүләтнең иң мөһим 34 функциясе тупланачак. Хәтта монархларның да кулында бу кадәр власть булмаган. Парламент киңәш бирү органы гына булып калачак, әгәр дә ул президент тәкъдим иткән хөкүмәт башлыгын расламаса, аны президент куып таратырга хокуклы. Ә президентның үзен законлы юл белән урыныннан алып булмаячак. Суд органнары исә сәяси авырлыкларын бөтенләй дә югалтачаклар.

Конституция проекты маддәләренең берсе халыкларның Русия эчендә үзбилгеләнү хокукына ия булулары турында белдерә. Мондый формулировка БМО Уставыннан башлап бөтен халыкара документларга каршы килә. Гражданлык һәм сәяси хокуклар турындагы халыкара пактның 1 нче маддәсе болай ди: «Бөтен халыклар да үзбилгеләнү хокукына ия. Шушы хокукка таянып, алар ирекле рәвештә үз сәяси статусларын билгелиләр һәм ирекле рәвештә үзләренең экономик, социаль һәм мәдәни үсешләрен тәэмин итәләр».

1993 елда Русиянең Гражданлык һәм сәяси хокуклар турындагы пактның факультатив беркетмәсенә кул куюы турында аерым әйтмичә булмый. Моның белән ул үз өстенә эчке законнарын халыкара законнарга туры китерү бурычын да алды. Әле бу гына да түгел, ул Кеше хокуклары буенча БМО комиссиясенең Русиядә кеше хокуклары бозылу турындагы шикаятьләрне каравына да ризалык бирде.

Күпмилләтле дәүләттә мөнәсәбәтләр бары тик астан өскә таба гына төзелә ала. Татарстан үз халкының ни теләвен ачыклау буенча бөтен таләп ителгән нәрсәләрне үтәде һәм бүген Мәскәүдән халык фикере белән исәпләшүне таләп итәргә хаклы. Әмма Мәскәү үзенең демократик потенциалын исраф итеп бетергәнгә охшый...

Татарстан һәм Русиядәге гомумсәяси хәлне Татарстан Республикасы суверенлыгының сәяси-хокукый базасын Русия кул куйган халыкара документларны Русия һәм Татарстанның рәсми делегацияләре ике ел буе алып барган сөйләшүләр нәтиҗәсендә туып Конституциябезнең 61 нче маддәсендә чагылыш тапкан формуланы күздә тотып, мин республика исеменнән БМОга һәм СБСЕга (Европада иминлек һәм хезмәттәшлек буенча киңәшмәгә) РФ Конституциясе проектының Русия үз өстенә алган халыкара бурычларга туры килү-килмәвен карауны, безнең суверенлыкка булган хокукыбызны яклауларын сорап мөрәҗәгать итү урынлы булыр дип уйлыйм.

Республикабызны яхшы белүче Мәскәүнең бер профессорыннан мин: «Татарстанның суверенлыгы Русиядә кемгә комачаулый?» — дип сораган идем. Ул моңа каршы: «Беркемгә дә комачауламый!» — дип җавап бирде.

## КУЛДАН ЫЧКЫНДЫРЫЛГАН МӨМКИНЛЕКЛӘР ЕЛЫ

### I. Язгы «нарциссизм»

арцисс исемле яшь кенә бер егет турында борынгы грек легендасы яши. Үз-үзенә сокланып, үз гәүдәсенең судагы чагылышын озаклап карый торгач, ул чәчәккә әйләнгән. Язын шушы легенда искә төшә...

Безнең яшь республикабызда бөтенесе дә бик дөрес... Җитәкчеләр ялгышмыйлар, шартнамәләргә һәм килешүләргә кул куялар...

Халык аларны тулысынча хуплый. Газета битләрендә «тәбрикләү сүзләре» тулып ята. Җитәкчеләрнең абруе зур, алар үз рейтингларын күтәрә баралар, дәүләт структуралары югарыдан бирелгән күрсәтмәләрне үтиләр, ә матбугат һәрьяклап уйланган һәм зирәк сәясәтне мактый. Массакүләм мәгълүмат чаралары чит илләрдән килгән мөһим кунакларны кабул итү, чит илләргә чиктән тыш әһәмиятле сәяхәтләр ясау турындагы мәгълүматлар белән тулып чыга. Интервью артыннан интервью китә, портретка кызыклы штрихлар өстәлә. Язгы «нарциссизм»...

Австриядә сәяси эшлеклеләр миннән, гафу үтенә-үтенә: «Әйтегезче, зинһар, Татарстан географик яктан кайда урнашкан ул?» — дип сорадылар. Ә канцлер Франц Враницкий: «Татарстан Түбән Новгородтан еракмы?» — дип кызыксынды. Һәм менә бу тышкы сәясәт дип аталган нәрсәнең нәтиҗәсе инде! Мәгълүмат хезмәтенең эш нәтиҗәсе! Чит илләргә күпсанлы сәяхәтләрнең нәтиҗәсе, шул исәптән Австриягә дә... Актив ыгы-зыгы (Мәскәү хакимиятендәге сайлауларны өзү һәм аны үткәрүдәге халыкара дәрәҗәдәге ыгы-зыгы) ничектер чын сәясәтне сиздерми генә алыштырды да куйды. Сәясәт ул — халык мәнфәгатьләрен чагылдыручы максатларны гамәлгә ашыру. Калганы ыгы-зыгы.

«Шок терапиясе» урынына бәяләрне көйләп тору тактикасын сайлап, без эшне дөрес башлаган идек. Агросәясәтне, халыкны адреслы яклауны дөрес билгеләдек. Һәм шуның белән тукталып калдык. Ясаган адымнарыбыз иҗтимагый тормышта реформалар үткәрүгә беренче якынаю гына булган бер вакытта кемнәрдер моны «реформаның үзе инде бу» дип игълан итәргә ашыкты һәм тәкәбберләнү башланды.

Башлары саклап калынган терлекләр! Ашамлыкларга иң түбән бәяләр! Бөртек өчен кукуруз! Сөт савуны арттыру! Русиянең болганчык диңгезендә муллык утравы!.. Бик шәп! Хәтта Мәскәүдә дә безнең агросәясәткә кызыктылар. Ә шул ук вакытта авылда реформа нәтиҗәләренә бернинди анализ ясау юк. Гади дотация исәбенәниләр алдык, нәтиҗәлелекне күтәрү исәбенә нәрсәләргә ирешелде? Авыл хуҗалыгын алып баруның кайсы формасы өметле? Базар механизмы авылда җитештерүне үстерүгә ни дәрәҗәдә булыша? Гадәти административ басым ясау юлы белән нәрсәләргә ирештек?

Нарциссизм... Яшүсмерләргә хас озакка сузылган яз авыруы... Барысы да берьюлы нәрсәнедер хуплый башласа һәм бер-бер артлы котлау телеграммалары яудырсалар, шикләнмичә әйтергә мөмкин — димәк, рәхәт торгынлык башланып килә...

Сәясәттә күзгә ташланып торучы ялгышлар булмау кайчак ялгышлык билгесе дә ул. Димәк, эзләнү юк. Эзләнсәң — тәвәккәллисең. Тәвәккәлләсәң — ялгышлар җибәрәсең. Төркия 1950 елда икътисадны либеральләштерергә омтылыш ясаган иде. Уңышка ирешә алмады. 1970 елда икенче омтылыш ясалды, монысы да уңышсыз булды. Һәм 1980 еллар башында өченче омтылыштан соң гына дөрес үсеш юлын таптылар. Ялгышлар җибәрә-җибәрә өйрәнәсең бит.

Якшәмбе көнне Чехов базарына барган идем һәм ничектер прилавка артында бер танышымны очраттым. Гыйльми дәрәҗәле галим, бик шәп белгеч. Иске радио детальләрен сатып тора. Берсе-берсе 100 сум... Ышанып әйтәм, яшь булса да, ул чит ил лабораторияләренә китмәячәк. Коммерция белән дә шөгыльләнә алмый — аңа яраклашмаган. Ул бары тик бер генә эшне белә — ачышлар ясый. «Борча» базарларында никадәр галимнәребез һәм сәләтле кешеләребез югалып кала безнең!

Мөгаен, күпләр үз-үзенә шундый сорауларны бирәдер: Татарстанның киләчәге нинди? Кая барабыз? Нәрсә телибез? Бу табигый сорауларга безнең ачык җавабыбыз юк.

Авыл хуҗалыгын һәрьяклап үстерергә кирәк, әлбәттә; әмма Татарстанның киләчәген бу гына билгеләмәячәк. Мин ышанам, сәүдә дә республика йөзен билгеләүче факторга әверелмәячәк, гәрчә үзебезнең географик хәлебезне мөмкин булганча киңрәк файдаланырга кирәк булса да. Бүген әһәмияте бик тә зур нефтехимия ике-өч дистә елдан соң, әйләнә-тирә мохитнең пычрануы аркасында, сәяси көрәш темасына әвереләчәк, һәм бу тармак аз-азлап кына тарая төшәчәк. Республиканың киләчәге — фәнни потенциалны, промышленностьны һәм банк капиталын бергә кушуга нигезләнгән югары технологияле продукция җитештерүдә.

Безнең киләчәгебезне нишләтәләр соң? Без әлеге «борча» базарларына галимнәребез һәм инженерларыбызны гына түгел, ә бөтен бер институтларны һәм тармакларны куып керттек. Аларны «Сникерс»ларга алыштырдык.

Дөрес, академикларыбыз күбәйде, халыкара конференцияләр югары дәрәҗәдә үтә. Әмма менә республика бюджетыннан төгәл финанслана торган Фәннәр академиясе шушы көнгәчә Татарстанның икътисади үсеше өчен нинди дә булса үрнәкне тәкъдим итә алмады. Ул республиканы түгел, ә үзен генә туендыра.

Билгеле, объектив кыенлыклар яшәп килә. Украинада, Казахстанда, Үзбәкстанда эш әйбәт түгел. Русиянең үзендә дә хәл начарайганнан-начарая. Бөтен җаваплылыкны Мәскәүгә аудару җиңел, әлбәттә. Тыныч кына кәнәфиеңдә утыра бирәсең. Әгәр «Терминал», «Вакууммаш»ның эш үрнәкләре булмаса, Казан заводлары базасында инициативалы яшь кешеләрнең нибары ел ярым вакыт эчендә эндохирургия өчен бик тә катлаулы җиһазлар эшләп чыгаруны җайга салуларын белмәсәм, мин дә, мөгаен, объектив кыенлыклар турында сөйләнүләргә ышанып идем. Бу уңышларга алар яшәп килүче шартлар нәтиҗәсендә түгел, ә шул шартларга каршы торып ирештеләр. Кайда соң безнең суверенитетыбыз? Өстенлекле тармакларны салым һәм кредит ягыннан кызыксындыра торган сәясәт кайда? Бездә киләчәк турында кем уйлый? Югары технологияләр, продукцияне урнаштыру базарларын яулап алу, алдынгы тармаклар өчен кадрлар әзерләү турында кемнәр уйлый?

Салым басымы турында күпме сөйлиләр. Җитештерү, фән, белем бирү системасы туктала. Шуңа да карамастан һаман яңа салымнар кертелә. Элекке җитештерү системасы ниндидер шайтан коткысы белән җимерелә, коммерсантларның яшь үсентеләре сындырыла. Хәзерге салым сәясәте асылы буенча җинаятьчел ул. Җәмгыятьне таркатучы. Ул җитештерү организмының барлык күзәнәкләрен тарката, законнарны иң күндәм үтәүчеләрне дә алдашуга барырга мәҗбүр итә. Хөкүмәт моны аңлый һәм хөкүмәт моны яклый!

Банк һәм финанс системасы — базар икътисадының нерв күзәнәкләре, кан тамырлары. Базар мөнәсәбәтләрендә финанс — иң зур һәм иң җитди сәясәт, ә финанс министры һәм Милли банк директоры — бөтен дәүләтнең сәясәтен билгеләүче кешеләр. Ә безнең Татарстанда төп, «сәясәтчеләребез»нең стратегик нияте нидән гыйбарәт? Үзәккә карата «мактаулы» лояльлектән тыш безнең алардан кеше төшенерлек берни дә ишеткәнебез юк. Русия Федерациясе белән хөкүмәтара килешүләрдә алар ирешкән нәрсәләр — Мәскәү министрлыкларында күп еллар буена дәвам иткән ыгы-зыгыны акларга маташу гына ул... Без суверенитет турында фикерләшкән арада, Мәскәү финанс империясенә әйләнде. Егерме дүрт сәгать эчендә ул Татарстанның бөтен банк челтәрен йота ала. Күп кенә банкларыбыз бөлгенлек чигенә җитте бит инде. Валлаһи дип әйтәм, шундый бер көн килеп җитәр, моның өчен Мәскәүгә финанс һәм банк системаларын тәртипкә салырга тотыну өчен бер җитди сәясәтче генә кирәк. Мин, бәлки, хәлне бик күңелсез итеп күрсәтәмдер. Бәлки, бераз түзәргә һәм структур үзгәрешләрнең үз җимешләрен бирүен көтәргәдер. Моңа бик тә ышанасы килә. Әмма, кызганычка каршы, нәкъ менә структур үзгәрешләр күренми. Галимнәр тәкъдиме белән һәм тендерлар нигезендә алдынгы проектларга һәм программаларга ташламалы кредитлар бирердәй инвестиция фондлары юк. Конверсия бармый. Оборона предприятиеләре кадрларына — галимнәргә, конструкторларга, эшчеләргә булган мөнәсәбәт «геноцид» дип атала. Гафу итегез, моның өчен мин йомшаграк сүз таба алмыйм. Чөнки алдынгы предприятиеләрнең үлем газабы кичерүен, фәнни мәктәпләрнең үлә баруын, белем бирүдә вуз системасының җимерелүен күреп, йөрәккә кан сава.

Хәрби промышленность комплексы буенча Русия Федерациясе белән төзелгән килешү эшләми. Хөкүмәт аклана белә: Русия ягы үз өстенә алган йөкләмәләрне үтәми, янәсе. Хөкүмәт кешеләрнең урамга чыга башлавын һәм үзен бәреп төшерүен көтә, күрәсең.

Белем системасы исәбенә бөтен дөнья алгы үрләргә чыга. Икътисадны үзгәртүне кешеләрне укытудан башлыйлар. Ә без аны җимерүдән башладык. Әлбәттә, хөкүмәтнең тагын акланыр нәрсәсе бар: вузлар Русия буйсынуында һәм Русиянең вузлар белән шөгыльләнмәвендә безнең гаеп юк. Эшлексез булуыбызны аклау технологиясен без яхшы үзләштердек. Татарстанда бөтен югары белем системасы җимерелгән хәлдә калачак һәм без яшьләребезне читкә, үзебезнекеләрдән йомшаграк университетларга укырга җибәрергә мәҗбүр булачакбыз, моның өчен долларлар түләячәкбез. Мондый хәлне ничек акларбыз? Ә бит без чит ил студентларын үзебездә укыта ала торган республикада яшибез.

Республика үз үсешендә динамизмны югалтты. Суверенитет әле, кызганычка каршы, яшәү рәвешенә әйләнмәде. Хөкүмәт һаман да әле «өлкә» фикерләве дәрәҗәсендә. Чөнки бу елларда министрлыкларның структурасы да, функцияләре дә үзгәрмәде. Хөкүмәттә тормыш «ТОРГЫНЛЫК» билгесендә туктап калды. Анда әле шушы көнгә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында Түбән Кама ГЭСы сусаклагычын су басу зонасына әзерләү бүлеге яшәп килә. Башкасы турында әйтеп тә тормыйм.

Татарстан хөкүмәте шушы көнгә кадәр Татарстан үсешенең икътисади моделенең асылын халыкка аңлатып бирмәде. Бу модельнең, бәлки, җитешсезлекләре бардыр. Беренче омтылышта ук аны, бәлки, гамәлгә дә ашырып булмас. Шулай да эзләнү кирәк, перспективасыз яшәп булмый.

Мин республика җитәкчелегенең нигез итеп ала торган сәбәпләрен аңлыйм — авыр чорда Русия фарватерында булу яхшырактыр. Чөнки хәтта БДБ илләре дә Мәскәүгә һәм сум зонасына сыенырга тырышалар. Ләкин, халыкара экспертларның фикеренчә, Русия сәясәте тулы уңышсызлыкка очрады. Икътисад һәм сум — эчке түләмәүчелек, күп айлар буена эш хакын бирмәү, халыкара оешмаларга бурычлар һәм чит ил кредитлары исәбенә яшәп килә. Русия киләчәк буыннарның өлешен ашый. Мәскәү нинди җәмгыять төзергә кирәген белми. Икътисади үсеш моделен дә сайлый белми. Социаль өлкә, мәдәният, идеология белән ниш-

лисен белми. Шулай булгач, һаман упкынга өстерәүче сәясәт фарватерында булу нигә кирәк? Мәскәү үзенең интеллектуаль потенциалын тотып бетерде инде, реформалар үткәрү өчен аның җитәрлек сәяси ихтыяры юк. Инициативаны провинцияләрдән күтәргә кирәк, Русиянең күп төбәкләре үз үсеш юлларын эзли башладылар инде. Ә без артка чигендек. Болай булырлык булгач, суверенитетны нигә игълан иттек соң, референдумны нигә үткәрдек, Конституцияне нигә кабул иттек?

Русия Федерациясе белән төзелгән Шартнамәгә кул куйганнан соң, хөкүмәттә күпләр җиңел сулап куйды — хәзер инде үз өстеңә җаваплылык алмасаң да була. Хәзер без Русия белән, барлык борчуларыбыз өчен Русия җавап бирәчәк. Түрәләр өчен суверенитет шунысы белән куркыныч — ул аларны халык алдында җавап бирергә мәҗбүр итә. Ә Мәскәү түрәләре белән уртак тел табарга мөмкин. Түрә түрәне һәрвакыт аңлый. Ә шул арада суверенитет, федерализм турында сөйләнергә һәм үз-үзеңнән канәгатьлек хисе татырга да мөмкин.

Нарцисс суга карап үзенең чагылышына сокланырга яраткан. Бүген исә үз-үзен яратучылар суга түгел, ә упкынга карый. Әгәр упкынга озак карап торсаң, упкын сиңа карый башлый...

## II. Хокукый дәүләткә — тайгак юлдан

Татарстан һәм Русия хөкүмәтләре арасында беренче килешүгә кул куелуга ел ярым вакыт узды. Бүген инде андый килешүләр унике, әмма җәмәгатьчелекнең әле аларның берсен дә күргәне юк. Алай гына да түгел, депутатлар арасында да һәм дәүләт структураларында да аларның тексты белән кем генә таныш икән?!

Әлбәттә, теләсә кайсы дәүләтнең серне саклауга хокукы бар. Әмма югары белем, экология өлкәсендә, бюджетка кагылышлы үзара мөнәсәбәтләр турында, милек мәсьәләләре һ.б. буенча килешүнең сер булып калуы сәер. Андый документларны һәрвакытта да газеталарда бастыру зарурлыгы булмый, аларны махсус басма итеп чыгарырга да мөмкин булыр иде. Ә икенче яктан алганда, алар безнең барыбыз өчен дә беренче һәм тарихи документлар бит. Шуңа күрә белгечләр, эшмәкәрләр генә түгел, ә бөтен халык аларның басылуын күптән көтә.

Ни өчен соң Татарстан хөкүмәте килешүләрнең текстларын шулай бик нык яшерә? Бу сорауга җавап табу өчен аларның эчтәлегенә анализ ясарга кирәк.

Бюджетта үзара мөнәсәбәтләр турындагы килешү шундый документларга хас сүзләрдән башлана: «Татарстан Республикасы Русия Федерациясенә тапшырган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шулай ук уртак программаларны тормышка ашыру өчен Русия Федерациясенең республика бюджетына түләү взносларын кертә, моның өчен...» Әмма Русиягә нәкъ менә нинди вәкаләтләр тапшырылган һәм безгә нинди уртак программалар өчен түләргә кирәк соң? Татарстан Республикасы Югары Советының мондый карарлар кабул итмәгәнлеге яхшы мәгълүм. Ә бит ул — Русиягә яки нинди дә булса башка дәүләткә вәкаләтләрне тапшыру турындагы мәсьәләне хәл итәргә хокуклы бердәнбер орган. Татарстан Республикасы Конституциясендә Русиянең хакимият органнарына вәкаләтләрне тапшыру турында берни дә әйтелми. Федераль хакимият органнарына вәкаләтләр тапшыру турындагы мәсьәләне хәл иткәндә хөкүмәт таяна ала торган хокукый документ кайда соң?

Бюджетта үзара мөнәсәбәтләр турындагы килешүнең Татарстан Республикасы һәм Русия Федерациясе арасындагы Шартнамәгә кул куелганчы ук кабул ителүенә күз йомып карыйк ди. Хәзер Шартнамәдә безне кызыксындыра торган сорауга җавап эзләргә омтылыйк. Бу эш җиңел булмаячак. II маддәнең 2 нче пунктында бары тик Татарстанның республика бюджетын төзү хокукы турында гына әйтелгән, анда Русия бюджетына түләүләр турында нинди дә булса өстәмәләр юк. Уртак вәкаләтләр даирәсен билгели торган III маддәдә бюджетта үзара мөнәсәбәтләр турындагы мәсьәлә ни өчендер гомумән чагылыш тапмаган. Әмма аның каравы IV маддәдә без Русия вәкаләтләренең тулы җыелмасын күрәбез. Бу маддә күп яктан Шартнамәнең төп маддәсе булганлыктан һәм Русия сәясәтчеләре РФ Конституциясенең көчен Татарстан территориясенә җәелдерү дәлиле итеп нәкъ менә шуңа таянганлыктан, төп темадан берникадәр читкә китеп, IV маддәнең асылы һәм әһәмияте турында фикер йөртеп алыйк әле.

IV маддә бөтенләе белән һәм тулысынча РФ Конституциясенең 71 нче маддәсен һәм Федератив шартнамәнең тиешле маддәсен кабатлый. Ул күрәләтә торып ике мәгънәне аңлата, ә төгәлрәге, анда Татарстанның бу вәкаләтләрне федераль органнарга тапшыруы турында күрсәтмәләр булмаганлыктан, мәгънәсез булып кала. Шунысын да искә төшереп китү урынлы булыр, республика Федератив шартнамәгә кул куймады, ә 12 декабрь референдумында Русия Федерациясе Конституциясен Татарстан халкы санга сукмады. Димәк, аның безнең территориядә көче юк, шунлыктан мондый мәсьәләне хәл итү өчен юридик нигез булып хезмәт итә алмый.

Аннары. Шартнамәдә IV маддәнең безнең территориядә гамәлдә булуы турында әйтелми һәм моны ничек тә булса читләтеп аңлап та булмый, чөнки андый очракта ТР Конституциясен РФ Конституциясенә тәңгәл китерергә кирәк булыр иде. Бу исә Шартнамәнең эчтәлегенә каршы килә. Шартнамә шуның өчен кирәк тә: без үз Конституциябез буенча яшибез, ә Русия үзенеке буенча яши. Ике Конституция тәңгәл килмәгән шартларда килеп чыккан бәхәсләрне хәл итү өчен Шартнамә кебек механизм кирәк. Шартнамәнең аеруча мөһим казанышларыннан берсе нәкъ менә шунда: безнең Конституция үзенең көчен саклый, һәм Русия хәзер бездән Татарстан территориясендә РФ Конституциясенең көчен тануны таләп итә алмый. Шулай итеп, Шартнамә 12 декабрь референдумы нәтиҗәләрен беркетеп куя, шунлыктан аны күренекле сәяси документ дип бәяләргә мөмкин. Әмма юридик яктан ул үзенең югары максатына җавап бирми.

Шартнамәдә IV маддәнең булуы ике төрле аңлашылып кына калмый, ә башка маддәләргә турыдан-туры каршы да килә. Мәсәлән, финанс, бюджет, таможня, оборона предприятиеләре һәм IV маддәдә язылган башка мәсьәләләр бер үк вакытта III маддәдә дә кабатланган, монысында инде алар бергәләп башкарылырга тиешле вәкаләтләр дип аңлатыла. Алай гына да түгел, аларны бергәләп башкару хөкүмәтләр арасында тиешле килешүләр белән беркетеп куелган. Димәк, IV маддә декларатив формада гына булып тора һәм аның Шартнамә текстына бернинди мөнәсәбәте юк булып чыга. Моның сәерлеге шунда, әлеге маддәне юридик яктан әһәмиятле дип аңлату Русия дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренең Русия Федерациясенең үз территориясендә үк Татарстанның яхшы ниятенә бәйлелектә булуын аңлатыр иде. Моннан да мәгънәсезрәк эшне күз алдына китерүе кыен. Русия суверен дәүләт буларак яшәп килде һәм яши, шунлыктан ул 71 нче маддәдә санап кителгән функцияләрне үти. Ә Шартнамәнең эчтәлеге буенча аның суверенитеты бары тик 23 февральдә генә, ягъни Татарстан белән Шартнамәгә кул куелганнан соң 7 көн үткәч кенә башлана булып чыга. Шартнамәдә IV маддәнең барлыкка килүен әлеге проектны раслаган кешеләрнең юридик белемнәре булмавы белән генә аңлатырга мөмкин.

Шулай итеп, Шартнамәнең тексты безгә «Русия Федерациясенә нинди вәкаләтләр тапшырылды соң?» дигән сорауга җавап бирми. Фикерләрем уйлап чыгарылган нәрсәләр булып аңлашылмасын өчен мин шундый ук мәсьәләнең Пуэрто-Рико мисалында ничек хәл ителгәнлеген күрсәтергә телим. 1975 елның 17 декабрендә АКШ белән Пуэрто-Рико арасында озак вакытка исәпләнгән Союз турында шартнамәгә кул куелды. Аның нигезендә Пуэрто-Рико оборона, тышкы сәясәт һәм валюта өлкәсендәге вәкаләтләрне АКШка ирекле төстә тапшырды. «Кушма Штатлар,— диелә 2 нче маддәнең «г» пунктында,— Ирекле ассоциацияләнгән Пуэрто-Рико дәүләтенең оборонасы өчен җаваплы һәм үзара халыкара мөнәсәбәтләрне корырга вәкаләтле». Бу маддә буенча Шартнамәдә: «Кушма Штатларның оборонага һәм иминлеккә кагылышлы законнары Ирекле Ассоциацияләнгән дәүләт өчен аларның положениеләре буенча көчендә кала. Президент һәм губернатор оборона һәм милли иминлек өлкәсендә консультацияләр үткәрәләр һәм хезмәттәшлек итәләр»,— дип каралган. Барысы да ачык — оборона өчен АКШ җавап бирә, шунлыктан АКШның законнары Пуэрто-Рико территориясендә гамәлдә була, моның өчен Пуэрто-Рико АКШ казнасына акча түли. Алар арасында валюта һәм таможня мәсьәләсе дә шул рәвешле хәл ителгән. «Кушма Штатлар валютасы Пуэрто Риконың бердәнбер валютасы булып тора. Кушма Штатларның валютага, акча системасына, алтын һәм көмешкә кагылышлы законнары Ирекле Ассоциацияләнгән Пуэрто-Рико дәүләте өчен аларның положениеләре буенча көчендә кала». «Гомуми базар» дип аталган 9 нчы маддәнең «б» пунктында болай диелгән: «Кушма Штатларның чит илләрдән кертелә торган товарларга карата булган законнары һәм тариф положениеләре Ирекле Ассоциацияләнгән дәүләт өчен көчендә кала». Шул ук вакытта Пуэрто-Рико, таможня җыемнары аның казнасына тапшырыла, дип тә өсти: «Таможня салымнары, импорт лицензияләре, тарифлар, Пуэрто-Рикода җыела торган салымнар, Пуэрто-Рикодан Кушма Штатларга ташыла торган сәүдә әйберләренә булган эчке еллык салымнар кебек үк, аларны җыю чыгымнарын чигергәннән соң, Пуэрто-Рико казначейлыгына кертелә: «керем» һәм «салымнар» дигән термин тар мәгънәдә генә аңлашылырга тиеш түгел, ул теләсә кайсы чыганактан алынган — турыдан-турымы яки читләтепме — теләсә нинди керемгә карата кулланылырга тиеш». Әнә шулай, Пуэрто-Рико һәм АКШ арасындагы Шартнамә гап-гади кешегә дә аңлашыла.

Хәзер Татарстанга әйләнеп кайтыйк. Югары Совет кабул иткән яки Президент кул куйган документларның берсендә дә Русия хөкүмәте үтәргә тиешле вәкаләтләрнең исемлеге күрсәтелмәгән, һәм бу вәкаләтләрне тапшыру шартлары турында да искәрмә юк. Димәк, Русия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында бюджет мөнәсәбәтләре турындагы әлеге килешүгә премьер-министр үз белдеге белән генә кул куйган. Моны исә башкарма хакимиятнең үз вәкаләтләрен арттырып җибәрүе, закон чыгару функцияләрен дә үз өстенә алуы дип кенә бәяләргә мөмкин. Мин үзем моны нинди дә булса усал ният белән эшләнгән нәрсә дип уйламыйм. Бу барыннан да бигрәк хокукый культураның булмавы белән аңлатыла. Кайбер башка килешүләр буенча да шундый ук нәтиҗә чыгарырга була.

Игътибар беләнрәк анализ ясасаң, килешүләрдә башка сюрпризларны да табарга мөмкин. Мәсәлән, банк эше, акча, кредит һәм валюта сәясәте өлкәсендәге килешүне алыйк. Ул да Русиянең федераль органнарына вәкаләтләрне бик юмарт бирүдән башлана. «Банк эше, акча, кредит һәм валюта сәясәте өлкәсендә яклар шуннан чыгып эш итәләр: валюта һәм кредитны җайга салу, акча эмиссиясе һәм федераль банклар Русия Федерациясе карамагында була, ә Татарстан Республикасының Милли банкы Русия Федерациясе Үзәк банкының состав өлеше булып тора». Әйтик, закон чыгару органы буларак Югары Совет үз функцияләрен шулай законсыз рәвештә басып алуны эченә дә йотты ди. Әмма Шартнамә текстында аның хокукларына тагын бер хаслану бар: Татарстан Милли банкы бик четерекле хәлгә куела.

Шартнамәнең II маддәсе Татарстан дәүләт хакимияте органнары карамагында гына булган вәкаләтләрне беркетә: «Алар Милли банкны аерым килешү нигезендә булдыралар»,— диелә. Мондый юридик тәгъбир, ә иң мөһиме, аннан килеп чыга торган практик нәтиҗәләр башка сыймый. Беренчедән, әгәр бу вәкаләт бары тик Татарстан карамагында гына булса, ул чагында ни өчен тагын РФ белән аерым килешү төзергә кирәк соң? Мондый процедура бер якка гына караган вәкаләтләргә түгел, ә бергәләп гамәлгә ашырыла торган вәкаләтләргә кагыла. Икенчедән, килешү төзүне, кем әйтмешли, Татарстан Милли банкын булдыру факты дип аңларга, димәк, аның директорын яңадан сайлауны оештыру дип аңларга кирәкме? Гадирәк итеп әйткәндә, хәзер Е.Богачев Милли банк директоры булып кала аламы? Өченчедән, ТР Конституциясе белән нишләргә, республиканың Милли банкы шушы Конституция нигезендә эшли бит инде. Югары Совет аның директорын да сайлап куйды. Конституциячел норма хөкүмәтара килешү белән каплана алмый, күрәсең. Мондый юридик каршылыклардан бары тик ТР Милли банкы директорын яңадан сайлау яисә килешүнең үзен гамәлдән чыгару юлы белән генә чыгарга мөмкин.

Хокукый дәүләт турында шулкадәр күп сөйләнде ки, без инде эшнең алга таба баруына ышана да башладык. Парламент законнар чыгара, ә хөкүмәт аларны үти, Конституция инде гражданнар өчен дә, түрәләр өчен дә мәҗбүри үтәлергә тиешле Төп закон булып тора, җитәкчеләр законга күндәм гражданнардан торган халык турында кайгыртырга бурычлы.

Тагын берничә килешүне карап үтик. Нефть турындагы килешүдә, «Татарстан Республикасы предприятиеләре — нефть һәм нефть продуктлары җитештерүчеләр... Русия Федерациясе законнарын кулланып эш итәләр...» диген сүзләрне укыйбыз (8 нче маддә). Промышленностьның оборона тармаклары буенча килешү түбәндәгеләрне күздә тота (4 нче маддә): «Русия Федерациясенең дәүләт идарәсе органнары Татарстан Республикасында урнашкан оборона тармаклары предприятиеләре белән үзара мөнәсәбәтләрендә «Оборона турында», «Русия Федерациясендә оборона промышленностен конверсияләү турында», «Дәүләт ихтыяҗлары өчен продукция һәм товар җибәрү турында» Русия Федерациясе законнары һәм башка закон актлары, шулай ук шушы килешү нигезендә эш итәләр». Әгәр боларның һәммәсе Югары Советтан чыкса, минем берни инди шигем булмас иде. Чөнки законнарны кабул итәргә дә, юкка чыгарырга да хокуклы орган ул. СССР законнарының гамәлдә булу вакытын озайта да, республикада Русия законнары көченең зарурлыгын таный да ала. Ә менә хөкүмәт үзенә закон чыгару функцияләрен ала алмый, Конституцияне бозып эш итә алмый. Югары Советны берәү дә куып таратмады бит әле, ТР Конституциясенең 59 нчы маддәсен берәүнең дә юкка чыгарганы юк! Һәм, гомумән, әйтик, мәгариф турындагы килешү «Русия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының мәгариф турындагы законнары нигезендә...» диген сүзләр белән башлангач, мондый килешүне төзүнең нигә кирәге бар? Андый очракта законны үтәү генә кирәк. Килешү шуның өчен төзелә дә: Русиянең хакимият органнарына буйсынучы вузлар безнең территориядә һәм Татарстан законнарына буйсыналар. Ике закон системасы бер-беренә тәңгәл килмәгән очракта хокукый каршылыкларны килешү төзү юлы белән хәл итү кирәклеге туа. Ә бездә бөтенесе киресенчә — килешү төзү аша Русия законнары гамәлгә кертелә һәм шуның белән законнарыбыз, Конституциябез бозыла. Хөкүмәт закон чыгару органына әверелә, ә Югары Совет күзәтүче совет роленә дә риза, күрәсең?!

Оборона тармаклары буенча килешүдә Русия законнары телгә алынган, ә Татарстан законнары бөтенләй онытылган. Моны ничек аңларга? 4 нче маддәдә язылган, «Русия Федерациясенең дәүләт идарәсе органнары корал һәм хәрби техника эшләү, үзләштерү һәм җитештерүнең озак вакытка исәпләнгән программалары буенча предприятиеләргә задание җиткерәләр» диелгән. Ә коралның характеры турында берни инди искәрмә юк. Татарстан Республикасы Конституциясенең күпләп юк итү коралын җитештерүне тыя торган 8 нче маддәсен бөтенләй онытканнар. Кул куелган килешү нигезендә Русия безнең предприятиеләрдә теләсә нинди төр коралны җитештерә ала. Ярый әле килешү үзе «эшләми», безне шул коткара. Әмма монысы инде башка тема.

Таможня килешүендә таможня пошлиналары, салымнар, акцизлар һәм җыемнарны бүлүне бюджетны җайга салу турындагы килешүгә җибәрүне аңлавы кыен, ә бу соңгысында әлеге мәсьәлә җайлап кына читләтеп үтелгән. Ярты республиканы ашата ала торган чыганак ич бу! Русия хөкүмәтенә мондый бүләк нәрсәне аңлата? Сүз уңаеннан әйтим, Шартнамәдә таможня килешүенең үзе турында «онытулары» гаҗәп. Бу

килешүгә моңа кадәр үк кул куелган иде бит инде, таможня җыемнары турындагы мәсьәләне күтәреп тә торасы юк иде. Кайчак, республика хөкүмәтен Казан фикереннән бигрәк Мәскәү фикере борчый дигән тәэсир кала.

Цитаталар күп китерелде, җитәр. Хокукый дәүләткә нинди бормалы юлдан баруыбызны әйтелгәннәрдән дә аңлап була. Калганын укучы үзе күрер. Килешүләрнең текстлары белән таныштырсалар, әлбәттә.

Шартнамә һәм кул куелган килешүләр Татарстан Республикасы Югары Советы алдына күп кенә катлаулы һәм принципиаль мәсьәләләр куя.

Беренчесе. ТР Конституциясен ачыктан-ачык бозучы хөкүмәт белән нишләргә? Без хәзер хөкүмәт кризисы халәтендә, әмма моны ачыктан-ачык әйтергә куркабыз. Хөкүмәт үзен Татарстан Югары Советы сайлап куйганны онытты.

Икенчесе. Байтак пунктлары белән ТР Конституциясенә каршы килә торган Шартнамә һәм килешүләр белән нишләргә? Моңа ике төрле якын килеп булыр иде. ТР һәм РФ Шартнамәсен халыкара килешү дип танырга һәм ратификацияләргә, шуннан соң инде ул Татарстан Конституциясеннән һәм эчке законнарыннан өстенрәккә әверелә. Болай эшләү нинди дер дәрәҗәдә хөкүмәтләр арасында кул куелган килешүләрнең законлы булуын «үткән число» белән танырга ярдәм итәчәк. Әгәр дә инде Шартнамәне халыкара документ дип карамасак һәм аны ратификацияләмәсәк, ул чагында килешүләр Конституция нормалары белән каршылыкка керә, димәк, алар гамәлдән чыгарылырга тиеш була.

Өченчесе. РФ Федераль җыенына сайлаулар нинди нигездә үткәрелде һәм депутатлар нәкъ менә нәрсәне яклыйлар?

## III. Автономияме яки суверенитетмы?

Мин үзем Русия Федерациясе Федераль җыенын сайлауга бармадым. Юк, миңа кандидатлар ошамаган өчен түгел, «Бердәмлек һәм алгарыш» партиясенең сәяси советы утырышында мин нәкъ менә М.Шәймиев һәм О.Морозов кандидатурасын тәкъдим иттем. Сайлыйсың икән инде, лаеклыларны сайларга кирәк. Әмма сайлау үткәрү өчен юридик нигезләр булмаганлыктан, шәхсән мин үзем тавыш бирүдә катнашмадым.

Без барыбыз да Русия Федерациясе Югары Советында Татарстаннан сайланган халык депутатларының эшен күзәтеп тордык. Алар үзләрен берни белән дә күрсәтмәделәр кебек. Республика файдасына карарлар кабул итүгә йогынты ясардай депутатлар табылмады. Татарстанга бөтен халык алдында пычрак атканда да Югары Советны ташлап чыгучылар күренмәде. Русия парламентарийлары алдында С.М.Шахрайның «референдум вакытында Татарстанда кан елга булып агачак» дигән сүзләре хәтеремдә калган. С.М.Шахрай соңыннан гафу үтенүне дә кирәк тапмады. Ә безнең депутатлар шулчак авызларына су капкандай утырдылар, компромисслар тактикасы белгеченең «могҗизалар» күрсәтүен ахырынача тыңладылар. Татарларга каршы яңгыраган авазлар хорына кушылучылар да һәм хәтта «дөреслекне эзләп» үзләренә ышаныч белдергән халыкны алдап Конституция судына баручылар да табылды. Ә инде «зирәкләре» дәшми калды, үзләренең шәхси эшләре белән мавыкты. Республикабыз мәнфәгатьләрен яклап ялкынлы речьләр белән чыгучы халык депутатлары да хәтергә кереп калмаган.

Яңа сайланган депутатлар нәрсә белән шөгыльләнерләр? Республикага карата аларның йөкләмәләре нинди? Әгәр РФ Конституциясе безнең территориядә гамәлдә булса, ул чагында Татарстаннан сайланган депутатларның функцияләре һәм алар эшчәнлегенең хокукый нигезләре ачык булыр иде. Әмма бүген Татарстан белән Русияне бәйләп торучы бердәнбер документ ул — Шартнамә. Шартнамәнең текстына мөрәҗәгать итик.

Бөтен Шартнамәдә иң мөһим фраза менә шушы: «Татарстан Республикасы, дәүләт буларак, Русия Федерациясе белән Русия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Русия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында хакимият вәкаләтләре чикләрен билгеләү һәм үзара вәкаләтләр бүлешү турындагы шартнамә нигезендә берләшә». Бу очракта Конституцияләргә таяну декларатив характерда гына, чөнки ике Конституция, асылда, үзара сыеша алмый. Татарстанның РФ субъектлары исемлегендә булуы шулай ук берни турында да сөйләми, чөнки реаль субъект булу — РФ Конституциясе буенча яшәү дигән сүз ул. Әмма Шартнамәгә нәкъ менә үз Конституциябезне саклап калу өчен кул куелды бит. Шартнамә Татарстан белән Русиянең барлык мөнәсәбәтләрен җайга сала торган бердәнбер документ ул.

Шартнамә текстында Русия Федерациясенең закон чыгару органнарында Татарстан вәкиллеге турында бер сүз дә юк. Ни өчен Шартнамәдә бу мәсьәләләр җайга салынмаган соң дигән сораудан читкә китеп, беренче нәтиҗәне чыгарыйк: РФ Федераль җыенына сайлау үткәрү өчен хокукый нигезләр юк. Шунлыктан бу сайлауны үткәрү турындагы карар бары тик сәяси фикерләрдән генә чыгып, Мәскәү җитәкчелеге белән үзенчәлекле компромисс, Шартнамәгә кул куйган өчен үзенә бертөрле түләү сыйфатында гына кабул ител-

де. Шәхсән мин моны бу карарны кабул итүгә ниндидер дәрәҗәдә курку, икътисади, социаль проблемалар алдында курку, Русиягә һөҗүм итеп килүче шовинизм һәм сәяси тотрыксызлык алдында курку йогынты ясагандыр дип уйлыйм. Моннан исә икенче нәтиҗә килеп чыга: сәясәт хокукка түгел, ә Русиядәге хәзерге тулаем хәлгә хас булган «революцион максатчанлык»ка таяна башлады.

Аяныч, әмма факт Татарстан, Русиягә ияреп, хокукый юлдан чигенә башлады. Без Русиядә дөрес булмаган юл белән эшләнгәннәрне читләтеп кенә законлаштырабыз. РФ Конституциясе проекты ашыгычлык белән һәм субъектларның фикерен исәпкә алмыйча әзерләнде. Федераль җыен турындагы положениене эшләүгә республикалар да, өлкәләр дә якын җибәрелмәде, шулай да без анда депутатларны сайладык. РФ Конституциясе буенча референдумда ничә кеше катнашканлыгын халык әлегәчә белми һәм, мөгаен, белмәс тә. Бу исә бирелгән тавышлар саны белән алдашырга мөмкинлек бирә. Нәтиҗәдә хәтта әкәмәт түбән нормалар куелган шартларда да РФ Конституциясен 32 (!) республика һәм өлкә кире какты. Юридик тел белән әйткәндә, бу бернинди федерация юк дигәнне аңлата. Мәскәүдә үзләрен легитимлы дип күрсәтү өчен хакимияткә ябышып ятучы бер төркем сәяси көчләр генә бар.

Хәзер моңа без дә үз өлешебезне керттек. В.Шумейконың бер интервьюсында Татарстанда булган сайлауларны Русия Федерациясе Конституциясен тану дип аңлатуы юкка гына түгел. Ләкин ул берникадәр ашыкты. РФнең закон чыгару органындагы үзебезнең вәкиллекне республика халкы шулай беркатлы гына аңлагандыр дип уйламыйм. РФ Конституциясе буенча үткәрелгән (дөресрәге, Татарстанда булмаган) референдум нәтиҗәләре үзенең юридик көче ягыннан сайлауларга караганда өстенрәк тора. Әмма факт барыбер факт булып кала — сәяси компромисслар яшәп килүче хокукый нормалар кысасыннан чыкты, без «үзебезне революцион тоту»ның гомумРусия дулкынына тартып кертелдек.

Әйдәгез, «легитим булмаган» парламентның үзебездән сайланган «легитим булмаган» депутатларына әйләнеп кайтыйк. Алар нәрсәдән чыгып эш итәргә тиешләр соң? Татарстанның статусы һәм вәкаләтләр күләме федерациянең башка субъектлары статусыннан аерылган шартларда нинди законнар кабул итәргә кирәк? Безнең территориябездә гамәлдә булмаячак законнар буенча аларга тавыш бирүнең мәгънәсе юк бит. Ә безнең территориядә Русиянең нинди законнары гамәлдә соң? Аларның исемлеге кайда? Бу сорау ачык кала...

Шартнамәнең ТР һәм РФне «берләштерү» турындагы пунктында Русиянең бөтенлеген саклау турында әйтелсә дә, бу әле Русия законнарының вәкиллекле органнар һәм депутатның статусы турындагы нормаларны да кертеп, Татарстан территориясендә автомат рәвештә гамәлдә булуын аңлатмый. «Берләштерү» дигән сүз сәяси-юридик яктан Татарстан һәм Русиянең ниндидер «союз»ын булдыруны аңлата. Әмма «Русия — Татарстан союзы»ның закон чыгару һәм башкарма органнарын булдырырга беркем дә җыенмый, әлбәттә. Димәк, мөнәсәбәтләр ассоциацияләшкән (инглизчәдән тәрҗемә итсәк, берләшкән, бәйләнгән) формада гына, ягъни байтак вәкаләтләрне РФнең федераль органнары башкаруына тапшыру аша гына була ала.

Даниянең Гренландия белән һәм АКШның Пуэрто-Рико белән мөнәсәбәтләре нәкъ шундый бит. Шунлыктан мин Кушма Штатлар белән Пуэрто-Рико арасындагы озак вакытка исәпләнгән Союз турындагы Шартнамә текстына иркенләп мөрәҗәгать итәм. Бу Шартнамәнең 11 нче маддәсендә болай диелгән: «Ирекле Ассоциацияләнгән Пуэрто-Рико дәүләте Кушма Штатлар сенатында һәм вәкилләр палатасында һәр палатада бер вәкил белән катнаша, алар бу постка Ирекле Ассоциацияләнгән Дәүләт законнары нигезендә сайланырга тиеш».

Мөнәсәбәтләр логикасы ачык: 1) Пуэрто-Рико үзенең күп кенә вәкаләтләрен АКШка тапшыра һәм шул ук вакытта үз территориясендә АКШның нинди законнары гамәлдә булуы турында килешә; 2) тапшырылган вәкаләтләр даирәсе буенча законнар кабул итүне күзәтеп тору өчен Конгресcның һәр палатасына берәр вәкил сайлана (АКШта сенатка һәм вәкилләр палатасына һәр штаттан икешәр сенатор сайлана — халык санына туры китереп); 3) вәкилләр АКШ законы буенча түгел, ә Пуэрто-Рико законы буенча сайлана, чөнки барыннан да бигрәк үз дәүләтең мәнфәгатьләре күздә тотылырга тиеш.

Озын-озын цитаталар китерүем өчен шелтәлиселәрен белә торып, укучыны АКШ тәҗрибәсе белән якынрак таныштырасым килә, шуннан башка безнең сәяси ялгышлыклар ясавыбыз котылгысыз, без инде аларны ясыйбыз да.

Пуэрто-Рико һәм АКШ Шартнамәсендә АКШның Пуэрто-Рико территориясендә гамәлдә булган законнарын кабул итү процедурасы каралган: «Ирекле Ассоциацияләнгән Дәүләткә кагылышлы теләсә нинди закон актын раслау алдыннан губернатор яки вәкил үзләренең каршы фикерләрен Конгресска җиткерергә тиешләр, Конгресс утырышында бу закон актын Кушма Штатлар мәнфәгатьләрендә кабул итүнең һәм актны әлеге Шартнамәгә туры китерүнең максатчанлыгы билгеләнә. Әгәр тиешле комитет яки комиссия карау өчен тәкъдим ителгән закон актына каршы фикерләрне тавыш бирү юлы белән якласа, Ирекле Ассоциацияләнгән Дәүләт әлеге закон акты положениеләрен аны тәмам кабул иткән очракта да үтәүдән азат ите-

лә. Бу параграф гражданнарның хокукларына һәм бурычларына, иминлеккә, оборонага, чит илләр белән элемтәләргә яки валютага турыдан-туры кагыла торган закон актлары өчен кулланылмый». Хокукый дәүләттә мөнәсәбәтләр әнә шулай урнаштырыла.

Татарстанның Русия белән хокукый мөнәсәбәтләрен, йомшак кына итеп әйткәндә, бүгенгедәй стандарт булмаган хәлдә саклап калып буламы соң? Катлаулы эш бу, шулай да мин аны мөмкин эш дип уйлыйм.

Федераль җыенга депутатларны сайларга түгел, ә вәкил итеп җибәрергә кирәк иде. Һәрхәлдә, Федерация Советына (бу РФ Конституциясенә дә каршы килми).

Аннары. Депутатларның бурычларын ачык билгеләргә кирәк. Моның нигезендә Татарстанның (ТР Югары Советы аша) вәкаләтләр даирәсен Русия Федерациясе органнарына тапшыру акты ятарга тиеш. Шуннан соң инде безнең депутатларның да катнашы белән эшләнә һәм кабул ителә торган законнар турында, депутатларның республика алдында җаваплылыгы турында сөйләргә мөмкин.

Русиягә вәкаләтләрне тапшыру факты, асылда, үзе, теләсә кайсы башка дәүләткә тапшырган кебек үк, республиканың суверенитетын чикләүне сөйләми. Биредә вәкаләтләрне тапшыруның иреклелеге төп критерий булып тора. Русиягә вәкаләтләрне ирекле тапшыру буенча юридик яктан рәсмиләштерелгән акт федераль органнарның бу функцияләрне бернинди тапшыру процедурасыннан тыш башкаруыннан өстенрәк. Ирекле бирелгән нәрсәләр шундый ук акт белән кире дә кайтарыла ала. Ә инде асылда башкарыла — көч хокукы белән башкарыла торганнары көч басымы нәтиҗәсендә генә «бирелә» ала.

Вәкаләтләр субъект тарафыннан федераль органнарга гына түгел, ә киресенчә дә бирелә ала. АКШ белән Пуэрто-Рико арасындагы Шартнамә мондый мөмкинлекне күздә тота: «Кушма Штатлар хөкүмәте вакыт-вакыт Кушма Штатлар карамагындагы вәкаләтләрне тулысынча яки өлешчә үтәүне Ирекле Ассоциацияләнгән Дәүләткә тапшыра ала, әмма биредә Ирекле Ассоциацияләнгән Дәүләт хөкүмәтенең аларны үтәргә ризалыгы кирәк». Татарстан белән дә шулай эшләргә мөмкин. Мәсәлән, Русия безнең республикага татар мәдәниятен һәм мәгарифне үстерү кебек вәкаләтләрне үтәүне тапшыра алыр иде. Без бу функцияне билгеле бер дәрәҗәдә үтибез дә инде. Әмма моны юридик яктан рәсмиләштерү, әлеге функцияләрне гомумРусия масштабында үтәү өчен тиешле структуралар булдыру һәм финанслауны ачып җибәрү яхшырак булыр иде.

Баштарак мин, Русия белән мөнәсәбәтләр ассоциацияләнгән рәвештә урнаша ала, дип махсус әйттем. Әмма «урнаша ала» дигән сүз «урнашачак» дигәнне аңлатмый. Бөтенесе дә сәяси ихтыярга бәйле. Бүгенге көндә республика мондый дилемма алдында тора: «салмак» кына автономиягә әйләнеп кайтыргамы, димәк, икътисадта, социаль өлкәдә һәм сәясәттә инде яулап алынганнарны югалтыргамы яисә суверенитетны сакларгамы, димәк, Русия белән ассоциацияләшкән мөнәсәбәтләрне ныгытуның катгый хокукый юлыннан барыргамы, икътисади үсештә үз моделебезне булдырыргамы һәм үзебезнең тышкы сәясәтне эшләргәме.

## IV. Тантана «сәясәте»

Тиздән без Чит ил эшләре һәм БДБ мәсьәләләре департаменты булдыру турында Президент Указы чыгуның ике еллык юбилеен билгеләп үтәчәкбез. Департаментның бердәнбер кешедән — халыкара мәсьәләләр буенча Президент киңәшчесеннән генә торганлыгын кемнәр генә белә икән? Ул — мәгълүмат-анализ бүлеге дә, беркетмә, юридик, БДБ, Европа, АКШ һәм Көнчыгыш бүлеге дә. Кыскасы, «Фигаро монда, Фигаро анда». Әгәр тышкы сәясәт кирәк булган булса, департамент төзегән булырлар иде.

Билгеле, чит илләргә сәяхәтләр җитәрлек ясала. Алар төрле дәрәҗәләрдә, ялгыз гына һәм төркем белән дә була, беркетмә саклана, килешүләргә кул куела, вәкиллекләр ачыла. Лимузиннар эскорт озатуында җемҗем иткән утлары белән урамнардан зур тизлектә чабалар, капотта Татарстан әләме җилферди, журналистлар делегацияләрне фотоаппаратлар белән каршылыйлар...

Тантана рухы саклана.

Массакүләм информация чаралары җитәкчеләребезнең һәр адымын бик юмарт яктырталар. «Шундый-шундый фирмадан эшкуарлар төркеме Премьер-министр белән бик тә мөһим проблемаларны тикшерә», «шундый-шундый ил парламентарийлары Татарстанның сәяси системасы белән танышу өчен Югары Советта булдылар», «вице-президент халыкара мөнәсәбәтләрнең мөһим мәсьәләләре буенча күп кенә илләрнең президентлары белән телефоннан сөйләште»... Газеталарны укыгач, янәсе, барлык илләр дә Татарстандагы вакыйгаларны күзәтеп торалар, Клинтон үзе безнең Президент белән очрашуны көтеп ала алмый һәм менә Татарстанны БМОның 182 нче әгъзасы итеп кабул итәчәкләр дигән тәэсир туа.

Тантаналар тәмамланды. Көндәлек тормыш башланды. Һәм без нәрсә күрәбез? Энергиянең күп өлеше юкка сарыф ителә. Мәшәкатьле ыгы-зыгы...

Чит ил капиталы катнашында бер генә зур проектның да гамәлгә ашканы юк, бер генә халыкара оешма белән дә контактлар юк, Казанда бер генә чит ил дәүләтенең дә консуллыгы ачылмады, бөтен тышкы

икътисади эшчәнлек чимал, барыннан да бигрәк нефть сатуга гына корыла. Нефтьнең дә әле ни дәрәҗәдә нәтиҗәле сатылуына төшенәсе бар.

Алданырга кирәкми — дөньяда безне беркем дә белми. Моның өчен әле без үзебезне берни белән дә күрсәтмәдек. Дөньяны гаҗәпләндерердәй берни дә җитештермибез, сәнгатебезгә дөнья дәрәҗәсенә җитәргә ерак әле, республиканы танысыннар өчен спортның да тиешле масштабка җиткәне юк.

Үз абруебызны күтәрү өчен без хәтта республика референдумы, Конституция киңәшмәсеннән чыгып китү, Русия парламентына сайлауларны өзү кебек «шау-шулы», халыкара матбугатның игътибарын җәлеп итә торган чаралардан да файдалана алмадык. Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы республиканы пропагандалау өчен эшләргә кирәк булганда көчсез, аның каравы ул үзенең мәгълүмат чараларына карата «карачкы» функциясен бик яхшы үти. Тормышта һәрвакыт шулай — акыл җитешмәүне мускуллар белән тулыландырырга тырышалар.

Татарстан турында Көнбатышның телевидение каналларыннан күрсәтеп була торган бер генә фильм да төшерелмәде, элементар буклетлар һәм юл күрсәткечләр юк. Татарстан флагы һәм гербы бик зур дефицит, аны Австриядә һәм Төркиядә долларга эшлиләр. Халыкара эшчәнлекне мәгълүмат белән тәэмин итү «нуль» сызыгында. Дөньяда Татарстан кебек суверен дәүләт яшәү турында белмәүләре гаҗәп түгел. Венгрия һәм Төркия белсә генә инде.

Бәлки, безгә мөстәкыйль тышкы сәясәт кирәк тә түгелдер? Бу функцияне Русиягә тапшырдык ич — хәзер аның башы авыртсын. Болай да була, әлбәттә. Чынлыкта эш шуңа таба бара да.

Шунысы кызык, хәтта «банан республикалары» дип аталган илләр дә тышкы сәясәт белән шөгыльләнәләр — шуннан башка товарыңны сата алмыйсың.

Үз промышленностебыз җитештергән әйберләрне кая сатып җибәрү турында бездә кем уйлый соң? Предприятиеләр товар белән тула. Әгәр предприниматель бу товарны читкә чыгарырга теләсә, товар күплектән җитештерү тукталып калса да, аны лицензияләр белән интектерәләр. Чикләребез ачык һәм җитештерүебез нәтиҗәсез булганда, импорт товары һәрвакыт хәтта үзебезнең эчке базарда да конкурентка сәләтлерәк булачак, тышкы базар турында әйтеп тә тормыйм. Әгәр җитештерүне үзгәртәбез икән, ул чагында нинди базарга исәп тотуыбызны беләбезме? Дөньяга чималдан башка нәрсә бирә алабыз? Электроникамы? Автомобильләрме? Медицина приборларымы? Шикләнәм. Дөнья базары мондый типта беренче класслы продукция белән күптән тулган инде.

Безнең предприятиеләр өчен дөньяда потенциаль базарларга эксперт бәяләмәсен Тышкы икътисади элемтәләр министрлыгы бирергә тиеш иде. Әмма бу министрлык мәгълүмат-анализ эшчәнлеге урынына турыдан-туры идарә итү белән шөгыльләнә, төгәлрәк әйтсәк, чит дәүләтләр белән сәүдә итүдә өстәмә киртәләр тудыра. Тышкы икътисади элемтәләр министрлыгы тышкы икътисади эшчәнлегебез өчен капкаларны киң ачасы урында бөтен эшчәнлекне «тар бугаз» аша гына үткәрә.

Шул ук вакытта безгә яңа технологияләрне үзләштерергә ярдәм итә торган чит ил инвесторлары һәм партнерлары өчен уңай шартлар тудыру турында уйларга кирәк бит. Шундый салым системасы яшәгәндә Татарстанда нинди чит ил кешесе эшләр икән? Моның өчен юләр булырга кирәктер. Бездә бит эш урыннары булдырган өчен салымнан азат итмиләр, киресенчә, өстәмә салымнар каералар. Предприятие ачу турында таныклык алу өчен айлар буе йөрисең, алгач та әле офис таба алмыйсың, ә артыңнан инде мафия ияреп йөри. Мондый шартларда чит ил милкенең ни дәрәҗәдә яклануы да мәгълүм түгел.

Бүгенге көндә бездә товар урнаштыру өчен ике реаль базар бар: Русия һәм Үзәк Азия. Безнең продукцияне шунда сатып алачаклар, үз продукциябезне чималга яки шундый ук конкурентлык сәләте булмаган товарга алыштыруны без шул базарларда эшли алабыз. Шунлыктан тышкы сәясәтнең иң мөһим бурычы — Русия һәм Азия базарында ныгып калу.

Русия белән бердәм икътисади киңлектә булу безгә базарда урыннарны автомат рәвештә генә бирми, аның өчен Уралда, Себер, Көньяк һәм Төньякта тиешле структуралар булдыру аша көрәшергә кирәк. Русиянең куәтле промышленность төбәкләре Русиядә дә, Азиядә дә реаль конкурентлар алар. Бөтенесе кемнең җитезрәк булуына бәйле.

Шуның белән бергә чиктәш төбәкләр белән тыгызрак кооперация һәм интеграция кирәк. Икътисади яктан гына түгел, ә этник яктан, мәдәни яктан да кирәк, шулай ук Идел-Урал төбәгендә сәяси тотрыклылыкны яклау кирәк.

Башкортстан, Мари Эл, Удмуртия белән дуслык һәм хезмәттәшлек турындагы килешүләргә кул куелуга инде берничә ел вакыт үтте. Ә алар үтәләме соң? Юк, үтәлми. Дәүләт аппаратында аларның үтәлүен контрольдә тотучы кеше дә юк. Алайса, нигә кул куйдык соң?

БДБ илләре белән дистәләрчә килешүгә кул куелды, әмма алары да нәтиҗәле эшләми. Аларның ни өчен кәгазьдә генә калуын тикшерергә беркемнең дә вакыты юк. Татарстанның Мәскәүдәге, Үзбәкстан, Азәрбайҗан һәм Литвадагы вәкиллекләре бу килешүләрнең үтәлүен тәэмин итә алырлар иде кебек. Әмма

бу вәкиллекләрнең кемгә буйсынырга тиешлеге турындагы мәсьәләнең хәл ителгәне юк. Тышкы икътисади элемтәләр министрлыгынамы? Әмма алар икътисади функцияләрне генә үтәп калмыйлар бит. Департаменткамы? Әмма табигатьтә булмаган нәрсәгә буйсынып булмый ич.

Бу айда мин Ташкентта булдым. Даими вәкиллекнең ничек эшләвен, бинаның ничек төзелүен карадым. Халык-демократик партиясенең беренче секретаре, Тышкы эшләр министрлыгы хезмәткәрләре, министрлар белән сөйләштем. Аларның барысы да Русия белән ике арада кул куелган Шартнамәне югары бәялиләр, Татарстан һәм Үзбәкстан арасындагы мөнәсәбәтләр ныгыр яки хәтта яңа дәрәҗәгә күтәрелер дип саныйлар. Әмма шунысы кызыклы, Үзбәкстанның рәсми кешеләре Шартнамә турында бары тик информация агентлыклары һәм Русия телевидениесенең җитәр-җитмәс хәбәрләре аша гына беләләр. Ә бит Ташкентта безнең вәкиллек бар. Ләкин аның Татарстан белән ышанычлы элемтәсе юк, ә информацияне очраклы йомышчылардан гына ала. Үзбәкстан Министрлар Кабинетыннан шылтыраталар, чит дәүләт илчелекләреннән шылтыраталар, гражданнар кызыксына. Шартнамә турында информация юк, килешүләрнең текстлары юк, Үзбәкстан Тышкы эшләр министрлыгы һәм Тышкы икътисади элемтәләр министрлыгы шулардан башка эшли алмый. Республика турында гади генә буклетлар да юк хәтта.

Без әнә шундый вак-төяктә оттырабыз, чөнки тышкы сәясәттә элементар тәртип юк.

Татарстанның тышкы сәясәте алдында икътисадка кагылмаган кайбер проблемалар да бар. Үзбәкстан Тышкы эшләр министрлыгында миңа татарларның китүе хакында борчылып сөйләделәр. Ә бит бирედә татарлар квалификацияле эшче көчләрнең шактый зур катламын тәшкил итә, күп татарлар дәүләт структураларында икътисад белән идарә итүдә эшлиләр. Аларның китүе Үзбәкстанның үсешендә чагыла. Икенче яктан, татарларның безнең республикага күпләп күчеп килүе катлаулы социаль проблемалар китереп чыгарырга мөмкин. Бу очракта һәр ике якның мәнфәгатьләре туры килә. Үзбәкстанда татар мәктәпләре ачу, телевидение каналы редакциясе булдыру, мәдәни үзәкләр төзү һ.б. аша проблеманы уртак тырышлыклар белән чишү юлын табарга мөмкин.

Татарстан һәм Русия Шартнамәсендә без республикабызның халыкара хокук субъекты булуы турындагы позициясен күрмәдек. Бу очраклы түгел. Сөйләшү процессының бер үзенчәлекле ягы бар — анда үзендә булганны гына яклап сөйләшергә мөмкин. Милкебез бар, без аны якладык. Нефтебез бар, без аның өчен көрәштек. Тышкы сәясәтебез булмый торып, аны ничек яклыйсың? Булмаган нәрсәне яклап булмый.

Промышленность, фәнни, мәдәни куәте нинди генә зур булмасын, үзенең тышкы сәясәтеннән башка Татарстанның перспективасы юк. Хәзер Якутия, Карелия, Дагстан кебек республикалар гына түгел, бәлки кайбер өлкәләр дә — Ленинград өлкәсе Петербург белән, Свердловск өлкәсе Екатеринбург белән, Калининград, Сахалин өлкәләре һ.б. тышкы сәясәтне тәэмин итү өчен кирәкле структураларны булдыралар, чит дәүләтләрнең консуллыкларын ачалар һәм бу проблемаларны үзләренчә эшлиләр, үзләренчә аңлыйлар. Безнең төп ялгышыбыз — гомуми тышкы сәясәтне эшләүче һәм чит ил партнерлары белән эшли торган төрле ведомстволар һәм предприятиеләрнең эшчәнлеген бергә туплаучы орган булмауда.

Бөтен дөньяда чит ил кунакларын каршылаганда билгеле бер «тантана»ны саклау бар. Әмма, гадәттә, сәламләү-котлау тостларыннан һәм кул кысышулардан соң көндәлек һәм авыр хезмәт башлана. Ә бездә халыкара сәясәтнең башы да, ахыры да тантанага корылган.

Ыгы-зыгы...

## V. Компас «акылдан язса», нәрсә эшләргә кирәк?

Магнит аномалиясенә эләксә, компас түгәрәк сызык буйлап әйләнә башлый һәм аның хәрәкәтенең юнәлешен билгеләве кыен була. Безнең җәмгыятебездә дә шундый ук хәл. Төп юнәлешләр юкка чыкты. Суверенитет өчен көрәшкәндә үзебезнең ни теләгәнебезне белә идек. Ә хәзер кинәт вакуумда калдык. Артка әйләнеп кайту мөмкин түгел, чөнки бер аягыбыз белән базарга килеп кердек. Ә тоташ базарга күчәргә ашыкмыйбыз. Демократия турында авызыбызны ачтык һәм куркып калдык — нәтиҗәдә тоталитаризмнан киттек, ә демократиягә барып җитмәдек.

Юнәлешен югалткан кеше бәргәләнә башлый һәм көчен югалта. Ул инде көчсез. Аңа ыгы-зыгы килмәскә, ә тыныч кына барысын да үлчәп-уйлап карарга, башта кая таба барасын билгеләргә кирәк иде югыйсә. Ә бәлки, аңа башын артка ташлап чабарга түгел, киресенчә, тукталып калырга һәм казына башларга кирәктер. Чөнки аномалия аяк астында ниндидер байлык ятуны искәртә бит.

Без үткән ел гафу ителмәслек дәрәҗәдә күп нәрсәне кулдан ычкындырдык. Иң зур капиталны — халыкның җитәкчелеккә ышанычын — икътисади реформаларны үткәрү өчен файдаланырга кирәк иде. Әмма бу нәрсә булмады. Хәзер реформаларны үткәрүе катлаулырак — акча юк, җитештерүнең кимүе һәлакәтле чиккә җитте, тормыш дәрәҗәсе кими, һәм, шулар нәтиҗәсе буларак, беренче җитәкчеләрнең популярлыгы кимү котылгысыз. Без республиканың тыныч үсүе мөмкинлеген кулдан ычкындырдык. Хәзер реформалар кризис шартларында барачак.

Мондый хәлдән ничек чыгарга? Хөкүмәткә бер ай эчендә тиешле программа эшләүне тапшыру җиңел, әлбәттә. Кызганыч, бу берни дә бирмәячәк, чөнки мондый программаларны Министрлар Кабинеты һәм Югары Совет күп тапкырлар карады инде. Дәүләт структураларының үзләрен үзгәртүдән башка нинди дә булса икътисади программаларны гамәлгә ашыруга керешүнең мәгънәсе юк. Республика Президентының вәкаләтләрен исәпкә алып, икътисади реформа буенча кайбер юнәлешләрне аңа гына тапшырырга мөмкин булыр иде, бу исә Министрлар Кабинетында яңартылган структуралар булдыру өчен акрынлап җирлек әзерләргә мөмкинлек бирер иде.

Күпләр шундый сорау бирә: Русия белән гомуми икътисади киңлектә яшәп, без нindидер радикаль реформалар үткәрә алырбызмы? Беренче карашка, юк. Әйтик, түләмәүчелек мәсьәләсен кем хәл итәр? Татарстан аны хәл итә алмый — суверенлыгы җитми. Ә Русия теләми. Моңа күпләр инанды инде. Ә менә Тверьда бернинди суверенитетсыз вексельләр керттеләр. Димәк, вексельләр белән проблеманың нindидер өлешен хәл итәргә мөмкин.

Иң төп бурычларның берсе ул — дәүләт, конкретрак әйтсәк, заказларны биргән һәм аның өчен түләмәгән Русия хөкүмәте. Мондый очракта түләмәүчелек проблемасы сәяси проблемага әйләнә. Һәм аны сәяси проблема итеп куярга кирәк тә. Шуның өстенә башка төбәкләр белән берләшергә кирәк. Күрше республикалар белән килешүләрне шуның өчен төзедек түгелме? «Зур Идел» ассоциациясен шуның өчен оештырдык түгелме?

Салымнар турындагы мәсьәләгә дә нәкъ шулай якын килергә мөмкин. «Без гомуми салым киңлегендә һәм аларны берьяклы тәртиптә генә үзгәртә алмыйбыз» — җитәкчеләрнең күпчелеге шулай уйлый. Һәм Русия салымнарына өстәмә рәвештә җирле салымнар кертә. Яңа салымнар кертү өчен суверенитет җитә, ә аларны киметергә юк. Кызыклы логика.

Русиядәге гомуми хәлгә бәя биргәндә, безнең икътисади үсеш проблемаларын мөстәкыйль хәл итүдән гайре юлыбыз юк, дип, ышанычлы төстә әйтергә мөмкин. Русия Федерациясе җитәкчелеге Б.Н.Ельцинга алмашка килүчене эзләү мәсьәләсе белән мәшгуль. Русиянең кая таба хәрәкәт итүен бүген беркем дә белми һәм бу хакта беркем дә уйламый. Икътисади төркемнәр яшәп килә, алар үз тарафдарлары аша хөкүмәттә өстенлек итәләр. Бу төркемнәрнең мәнфәгатьләре үзара бәрелешүе нindидер гомуми юнәлеш бар дигән фикер тудыра. Русиядә реформалар түбәннән барачак, һәм бүген күп төбәкләр кризистан мөстәкыйль чыгу юлын эзлиләр. Ә без һаман көтәбез. Нәрсә көтәбез?!

Базарга «йомшак» керү буенча элекке сәясәтебез тулысынча искерде инде һәм хәзер яңа икътисади курс кирәк. Мин аны ничек күзаллыйм соң?

1. Барыннан да бигрәк бәяләрне, эш хакын һәм тарифларны көйләп тору системасы таләп ителә.

Без хәзер шундый хәлдә ки, әйтик, ягулык-энергетика системасында бәяләрнең һәм тарифларның чиктән тыш югары булуы сәбәпле, күп кенә предприятиеләр продукциясенең бәясе дөнья бәяләренә якынаеп килә. Продукцияне урнаштырып булмый. Татарстанның зур-зур заводлары эштән туктый. Кешеләр эшсез кала. Шул ук вакытта уртача эш хакы энергетикларның, мәсәлән, республика Президентыныкыннан югарырак һәм 600 мең сум тәшкил итә.

2. Җитештерүне җанландырып җибәрү өчен республиканың акылга нигезләнгән үз салым сәясәте кирәк.

Җитәкчеләр арасында кайберәүләр, салым басымы кимесә, бюджетка керем азаячак дип куркалар. Бюджетка керемнәр инде болай да берничә тапкыр кимеде бит — салым күләмнәре бюджетның керем өлешенә йогынты ясамый башлады.

Җитештерүне җанландыру берничә проблеманы хәл итә: кешеләр эш хакы ала, ә шуның белән бергә халыкның сатып алу сәләте саклана: яңа эш урыннары барлыкка килә; әйләнешне арттыру һәм җитештерүне киңәйтү исәбенә бюджетка салым керемнәре арта.

Салым сәясәтенең социаль ягы да бар — ул кешеләрне законны бозуга этәрергә тиеш түгел. Җинаятьчелекне икътисади-сәясәт принципларына аударырга кирәкми.

3. Ташламалы салымнар, максатчан кредитлар бирү һәм махсус инвестиция фонды булдыру аша фән казанышларына нигезләнгән технологияләрне хуплау.

Без «Республиканың киләчәге нәрсәдә?» дигән сорауга җавап бирергә тиешбез. Безгә — республика халкына — оборона комплексы нәрсәгә? Без халыкка проблемалардан гайре берни дә бирмәүче милитаризацияләнгән икътисад белән яшәргә җыенабызмы яки инде җәмгыятьтә башка өстенлекләрне таныргa һәм конкурентлык сәләте булган продукция җитештерү өчен ХПКның гаять зур фәнни һәм кадрлар потенциалын файдаланырга тиешме?

Кемдер хәрби комплексны тергезүгә һәм корал сатуга өметләнә. Хыял гына бу. Элекке милитаризацияләнгән икътисадны торгызу өчен Русиянең акчасы да, көче дә юк. Шуның өстенә соңгы елларда ул дөнья-

дагы барлык корал базарларын югалтты. Аның урынын башка илләр алды. ХПК икътисади һәм социаль яктан авыр йөккә әверелде, ул конверсия очрагында гына перспективалы була ала.

Республиканың киләчәге — икътисадны хәрбиләштерүдән арындыруда. Безгә нейтраль дәүләт булу файдалы. Дөньяда чәчәк атмаган нейтраль дәүләт юк әле. Мәсәлән, Латин Америкасында бер генә ил — Коста-Рика гына — үзен нейтраль дәүләт дип игълан итте. Һәм бөтен континентта сәяси яктан тотрыклы һәм икътисади яктан чәчәк атучы бердәнбер ил ул.

Без үзебезне тынычлык, фән, белем, югары технологияләр республикасы дип игълан итәргә, бөтен салым, кредит сәясәтен фәнгә нигезләнгән перспективалы тармакларны үстерүгә юнәлтергә тиешбез.

4. Республиканың икътисади иминлеген тәэмин итү максатында хосусыйлаштыру программасына төзәтмәләр кертү һәм бу эшне тизләтү.

Мәскәүдәге аерым икътисади төркемнәр хәзерге предприятиеләрне ясалма рәвештә бөлгенлеккә төшерү өчен шартлар тудырырга тырышалар. Аннары бу предприятиеләрне хосусыйлаштырачаклар, бу инде җылы яңгырдан соң күпләп чыккан гөмбәләрне җыюга охшап кала. Финанс хәлебезнең йомшаклыгын һәм халыкның ярлылыгын исәпкә алсак, республика милкенең кемнәр кулына эләгәчәген алдан ук әйтүе кыен түгел.

5. Банк системасына реформа.

Мәскәү финанс империясенә әверелде. Русиянең төп капиталы аның кулында тупланган. Татарстанның хәтта иң куәтле банклары да Русиянең аеруча йогынтылы банклары рәтенә керми. Башкача әйткәндә, якын киләчәктә алар Мәскәү банкларының филиалларына әйләнәчәкләр. Ә болары хосусыйлаштыру режимын да, структур үзгәрешләрнең юнәлешен дә көчләп тагачак. Әгәр алар Татарстанны «банан республикасы» итәргә телиләр икән, бу шулай булачак та. Асылда, безнең үз банк системабыз юк.

Югарыда санап кителгән бурычлар икътисади реформалар юлындагы төп һәм кичектергесез чаралар гына. Безгә шулардан башларга кирәк. Алга таба ничек хәрәкәт итәргә икәнлеген тормыш үзе күрсәтер.

Җәмгыятьне алга таба демократияләштерү — реформаларның иң мөһим юнәлеше. Моңа исә республикада хакимиятне үзәк кулында гына тупламау, ягъни вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны түбәнгә — проблемалар реаль хәл ителә торган урыннарга тапшыру да керә. Казанда турыдан-туры идарә итү белән шөгыльләнергә кирәкми, ә гомуми сәясәтне, икътисадны һәм дәүләтнең эшчәнлеге шартларын билгеләү кирәк.

Русия матбугаты аша, янәсе, базарга күчү авторитар режимны, гадәттән тыш чараларны һәм көчле хакимиятне таләп итә дигән дөрес булмаган фикер урнашты. Әгәр Төркия тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итсәк, без 80 нче елларда реформаларның уңышы нәкъ менә хәрби режимнан баш тарту һәм җәмгыятьне эзлекле демократияләштерү белән бәйләнгәнлеген күрербез.

Ниһаять, соңгысы. Мәкаләләремнең бу сериясен мин шушы иң мөһим фикерем белән төгәлләргә теләр идем. Минем инануымча, республикада икътисади реформалар үткәрү Русия белән үзара мөнәсәбәтләр мәсьәләсенә яки Татарстан үсешенең икътисади үрнәген эшләү проблемасына бәйләнмәгән. Бүген бу мәсьәлә — сәяси ихтыяр мәсьәләсе. Башкача әйткәндә, реформаларны башлау өчен тәвәккәллек һәм аларны үткәрү өчен команда кирәк.

Без шуны аңларга тиеш, икътисади һәм социаль проблемаларны безнең өчен беркем дә — Русия дә, Көнбатыш та хәл итмәячәк. Без үзебезгә үзебез генә ярдәм итә алабыз. Ә моның өчен берминди икеләнүсез Татарстанның инде «милли» сыйфатына әйләнгән үтә дә сак булудан башка гына эшләргә кирәк. Әйе, ялгышлыклар булыр. Реформалар юлын үткәндә ялгышмаган ил булмагандыр. Реформалар барышында үзебез сайлаган курска төзәтмәләр кертүнең дә кирәк булуына әзер булыйк. Ялгышлыклар — уңышка бару юлында шулай ук кирәкле элемент ул.

Сәяси ихтыяр реформалар өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга сәләтле кешеләр булуны күздә тота. Бу кешеләр үзләренең популяр булмауларына, курсны тормышка ашыруның бөтен авырлыгы алар өстенә төшәчәгенә һәм тәнкыйть утын үз өсләренә алырга әзер торырга тиешләр. Башка юл юк. Икътисади реформалар үткәрү өчен менә дигән бер ел вакытны югалттык. Әмма безнең әле мөмкинлек бар. Әгәр бу елны да кулдан ычкындырсак, ул чагында барысын да югалтырбыз.

# РУСИЯ ҺӘМ ТАТАРСТАН:
# ТАРИХИ ЮЛЛАР ЧАТЫНДА

## I. Чечен кризисы «җимешләре»

азан белән Мәскәү арасындагы мөнәсәбәтләргә элек-электән, борынгы заманнардан ук көндәшлек төсмере хас. Бүген дә Казан белән Мәскәү арасында бәхәс бара. Монысы, тоталитаризмга кире кайтыргамы, әллә демократияләштерүне дәвам итәргәме дип, Русия ике тарихи юлның берсен сайлау алдында тор-

ган вакытка туры килде. Туры килү димәктән, Мәскәү Грозныйны штурмлаган чагында, Гаагада Татарстан инициативасы буенча советлардан соң барлыкка килгән күп кенә дәүләтләрнең тынычлык акциясе үткәрелде. «Гаага инициативасы» дәүләт төзелеше проблемаларын хәл итүнең тыныч юлын күрсәтүе белән генә түгел, ә моның Татарстан оештырган беренче җитди тышкы сәяси акция булуы белән дә әһәмиятле. Хәзер ачыктан-ачык әйтергә мөмкин: Казан дөньякүләм мәйданга халыкара инициативалар субъекты буларак чыкты.

Русиянең перспективалары нинди дә, яңа сәяси ситуациядә Татарстан нәрсәгә исәп тота ала?

16 февральдә без Борис Ельцинның федераль җыелышка адресланган мөрәҗәгатен тыңладык. Ул сәяси һәм икътисади кризис котырынган көннәрдә бәян ителде. Ил халкы да, чит илләрдә дә бу мөрәҗәгатьне, Русия кайсы якка юл тотар икән дип, зур киеренкелек белән көттеләр. Б.Ельцин бу юлы да демократия яклы булуын раслады шикелле, әмма зур авырлык белән.

Чечнядагы вазгыять ил өстеннән контроль урнаштырырга маташучы «сугыш партиясе» өчен чирканчык алып карау иде. Җае да уңай килеп тора: халыкның тормышы көннән-көн начарлана, җитештерү кими, эшсезлек үсә һәм шушыларга өстәп демократик реформаларга карата өметләр сүрелә. Әмма реванш барып чыкмады.

Империячел көчләрне сөрлегеп калырга мәҗбүр иткән әһәмиятле факторларның кайберләрен билгеләп үтик:

— үз халкына таянган чечен гаскәрләренең «каты чикләвек» булып чыгуы. Грозныйда сугыш операцияләре башланганчы, бәлки, алар «хәрби төркемнәр» генә булганнардыр, әмма бүген безнең күз алдына регуляр, хәрәкәтчән, сугыш шартларына өйрәтелгән һәм, җитмәсә, Русиянең хәрби машинасына сабак биргән, яңа көрәшләргә әзер торучы армия. Сугыш хәрәкәтләренең ахыры ничек булып бетәр — монысы билгесез, әмма бер нәрсә бәхәссез: Мәскәү Чечняда җиңелде, чөнки сәяси мөнәсәбәтләрдә көчләү куллану факторы көтелгән нәтиҗәне бирмәде;

— массакүләм мәгълүмат чараларының күпчелеге бомбага тотуларга һәм чечен кризисын көч кулланып хәл итәргә каршы чыкты. Шулай итеп, алар үзләренең шактый дәрәҗәдә бәйсез демократия принципларына тугры булуларын расладылар;

— Чечня мисалында үз хокукларына да кул сузуны күргән республикалар каты торуга күчтеләр. Идел буе һәм Урал республикалары башлыкларының Чабаксарда бәян ителгән белдерүе күп кенә кайнар башларга бозлы су кебек тәэсир итте;

— ниһаять, җәмәгатьчелек, Аналар комитетлары һәм төрле партияләрнең фикере. Мәгълүм булганча, Чечнядагы операцияне бары тик Жириновский һәм Шахрай партияләре генә турыдан-туры һәм берсүзсез якладылар, ә калган партияләр теге яки бу формада мәсьәләдән читләштеләр, бу акцияне һәм аны үткәрү ысулларын гаепләп чыктылар. Хәер, күп кенә партияләр моны үз җайларын көйләү өчен эшләделәр.

Социологик мәгълүматларга караганда, Татарстанда үткәрелгән сораштыруда катнашучыларның 8 проценты гына конфликт тәртипне ныгыту өчен кирәк дип саный, чечен кризисына битараф калучылар исә нибары 2 процент тәшкил итә. Халыкның 90 проценты Чечнядагы сугышка каршы. Үзәкнең Чечнядагы кыланышларын гаепләп чыккан партияләр һәм хәрәкәтләр арасында бердәнбер искәрмә — Дәүләт Думасы депутаты Иван Грачев кына. Бу — хурлыклы факт. Ничә еллар дәвамында «мин — демократ» дип күкрәк каккан бу кеше тоталитар алымнар куллану тарафдары булып чыкты.

Тарихи масштабта империянең, билгеле, киләчәге юк, әмма аңа әйләнеп кайтырга маташулар булачак һәм бүгенге көндә Русиядә аның төп идеологы ролен А.Солженицын уйный. Ә чын сугышлар исә 1996 елда — президентлыкка кандидатлар күрсәтү вакыты җиткәч башланачак. Күп кенә сәяси хәрәкәтләр Ельцинны батыру юнәлешендә, асылда, шовинизм базасында берләшерләр дип фараз итәргә мөмкин. Ни өчен мөмкин, чөнки бу мантыйк элек А.Сахаров идеяләренә табынган демократларның хәзер алардан баш тартуыннан килеп чыга.

Боларга кем каршы чыга ала? «Демократик көчләр» бүген бердәм фронт түгел һәм үзләренең реформаторлык потенциалларын җуеп бетерделәр диярлек. Алар, әлбәттә, башкалада утырулары һәм күп кенә мәгълүмат чараларына контрольлек итүләре белән сәясәткә һаман да йогынты ясыйлар. Ләкин, кызганычка каршы, алардан яңа инициатива көтүе авыр.

Инициативалар астан — төбәкләрдән чыгачак. Реформалар беренче чиратта республикаларны кызыксындыра. Демократия һәм федерализация алар өчен сәяси һәм икътисади статусны саклап калуның, димәк, перспективаларның да төп шарты. Соңгы вакыттагы вакыйгалар күрсәткәнчә, Идел буе һәм Урал республикалары бүген аеруча актив сәяси көч буларак чыгыш ясыйлар. Алар гаять зур экономик потенциалга ия, алар этник составлары буенча чуар һәм аларның проблемаларын Солженицынча хәл итеп булмый.

Көнбатыш дәүләтләре дә Русиядә демократияләштерү процессларының дәвам итүен телиләр. Хәер, аларның иң зур теләкләре тотрыклылыкны саклап калу һәм моның өчен алар демократиянең мәгълүм бер

өлешен корбан итәргә дә әзер. Шул ук вакытта Көнбатышта Русиядәге тоталитар «тотрыклылык» дөньяны болгатып ташламагае дип шүрлиләр. Шуңа күрә аның үз-үзен тотышы бик үк эзлекле түгел.

Халыкара җәмәгатьчелекнең Чечня кризисындагы роле гыйбрәт алырлык. Б.Клинтонның һәм Европа дәүләтләре лидерларының Грозныйдагы операцияләрне яклавы хәрбиләрнең кулын чиште. Республикаларда исә Көнбатышның мондый позициясе төшенкелек уятты. Әмма тыныч халыкны бомбага тотулар башлангач, бу бөтен дөньяны тетрәндерде һәм Европаның күпчелек политик лидерлары карашларын үзгәрттеләр. Хәзер алар Б.Ельцинны ничек тә сугыш характерын үзгәртүгә таба этәрергә тырышалар. Европа Советының Парламент Ассамблеясы үзенең 1995 елның 2 февралендә чыгарган 1055 нче Резолюциясендә фикерен шактый кистереп әйтте: «Чечня белән Русия федерациясенең үзәк властьлары арасында сәяси низаг эчке эш булса да, бу властьлар кулланган алымнарны Ассамблея Русиянең халыкара йөкләмәләрен бозуы дип саный». Шул юллардан соң Резолюциянең күп кенә пунктларында Русиянең үз өстенә алган халыкара йөкләмәләрне һәм кешенең элементар хокукларын җитди бозуы билгеләп үтелә.

Сәясәтчеләр принциплардан түгел, ә мәнфәгатьләрдән чыгып эш итәләр. Үзләренә файдалы булганда, алар Югославия республикаларының үзбилгеләнешен һәм СССРның таркалуын якладылар. Бүген исә алар Абхазия, Приднестровье һәм Чечняның үзбилгеләнүгә булган дәгъваларын кире кагып, территориаль бөтенлек принципларының кагылгысызлыгы турында сөйлиләр. Төрле халыкларга төрлечә килеп, ике төрле стандарт куллану — сәяси чынбарлыкның күңелсез ягы һәм бу җирдә тынычлык урнашуга һич тә ярдәм итми. Чечнядагы хәлләр уңаеннан Көнбатыш алган позиция кеше һәм халык хокукларының, 1948 елгы Женева конвенциясенең, күп кенә халыкара документлар һәм килешүләрнең бозылуына китерде. Бәлки, Көнбатыштагы лидерлар шулай килеп чыгар дип көтмәгәннәрдер. Әмма нәкъ менә алар Русиянең «сугыш партиясенә» гөнаһларны ярлыкау кәгазе бирделәр. Бу рәхимсез сабактан нәтиҗәләр чыгарырга кирәк.

*Беренче нәтиҗә.* Югославия тәҗрибәсе һәм СССР беткән җирлектә туган дәүләтләрдәге конфликтлар сугышның беркемгә дә уңыш китермәвен раслыйлар. Сугышучы яклар, хәтта җиңгән очракта да, тупикка терәләчәк. Димәк, низагларны тудырмас өчен халыкара җәмәгатьчелек кулында булган бөтен чараларны кулланырга һәм сугыш операцияләрен эчке эшләр дип аклаудан сакланырга кирәк.

*Икенче нәтиҗә.* Тыныч халыкка карата көч куллануның бер чиге бар, шуңа күрә территория бөтенлеге принцибы абсолют характерда була алмый. Көч куллануның табигый чиге — кеше һәм халык хокукларының бозылуы.

*Өченче нәтиҗә.* Халыкларның үзбилгеләнү принцибын сәяси лидерларның теләсә нинди кыланышын аклаучы абсолют принцип дип аңларга ярамый. Ләкин әгәр дәүләт халыкны изә һәм аның яшәешен куркыныч астына куя, халыкара йөкләмәләрен үтәми икән, үзбилгеләнү бу халыкның дәрәҗәсен саклап калуның төп гарантиясенә әверелә.

Бер генә дәүләт тә бүген аерым гына яшәргә дәгъва кыла алмый. Бөтен халыкара җәмәгатьчелек өчен бердәм халыкара хокук нормалары бар. Үз файдаңны кайгырту максатларыннан чыгып, әлеге нормаларның аерым юнәлешләрен җинаятьчел эчке сәясәтне аклар өчен кулланырга ярамый. Соңгы чиктә бу конкрет дәүләткә карата гына түгел, ә бөтен кешелеккә карата кире ягы белән әйләнә — тотрыксызлык, сугышлар китереп чыгара.

Тагын шуны басым ясап әйтергә кирәк, шушы еллар дәвамында Европа дәүләтләренең һәм бигрәк тә АКШның аналитиклары Русиядәге хәлләрне дөрес бәяләмәделәр һәм бөтен дөньяда кабул ителгән демократик традицияләргә тәңгәл килмәүче күп кенә вакыйгаларны аклау юлыннан бардылар. Мисал өчен, Русия Федерациясенең закон чыгару органын утка тоту Б.Ельцинның мактаулы эше дип бәяләнде. Ә бит бу эш Чечня вакыйгаларының прологына әверелде. Нәкъ менә шул чагында Русия җитәкчеләре политик чишелешләрне хәрби эшләр белән алмаштырдылар, оппозициягә каршы киләчәктә дә танклар куллану мөмкинлегенә ышандылар. Реаль вакыйгалар турында экспертлар Мәскәү газеталарыннан чыгып фикер йөрттеләр, ә республикаларда булып та карамадылар диярлек. Республикаларны «консерватив провинция» дип атап, алар бары тик үзәк хөкүмәткә генә йөз тоттылар. Русиянең яңа конституциясе турында сүз күтәренке рухта гына алып барылды, ул алсу төсләрдә генә күрсәтелде, гәрчә Конституциянең маддәләрендә чечен синдромына инде ерак калмаганлыгын бик җиңел чамаларга була иде. Халыкара экспертлар Русиянең политик культурасын, бу культурага үз законнарын системалы рәвештә бозу хас булуын әле һаман да аңлап бетермиләр. Русиядә яңа лидер килгәннән соң яңа Конституция кабул ителәчәк. Моның шулай булачагына шикләнмәскә мөмкин. Ник дигәндә, әлеге Конституция төп закон түгел, ә патшалык билгесен чагылдыручы зиннәтле таяк кебек, кемгәдер яраклаштырылган власть символы гына бүген. Русиядә федерализацияләү һәм демократияләштерү гарантияләрен законнардан түгел, ә сәяси көчләрнең ничек урнашуыннан эзләргә кирәк.

Америка экспертлары үз бизмәннәреннән чыгып фикер йөртәләр һәм шуңа күрә Мәскәүдәге күп кенә политикларның Русияне территориаль принцип буенча үзгәртеп корырга омтылуларын аклыйлар. Чынлык-

та исә моның артында тотрыклылыкны юкка чыгару куркынычы тора. Республикаларның статусын яки чикләрен үзгәртергә маташулар көч кулланунның тоталь характерына китерәчәк һәм дөньяны авыр сынауларга дучар итәчәк.

Демократияне Мәскәүдән, өстән торып көчләп тагып булмый, дөньяда федерациянең әзер формалары юк, Русияне демократик башкалага һәм консерватив провинциягә бүлү ахмаклык.

Гыйнвар аенда «Уоллстритджорнал»да Клаудия Россетның «Татарстан аю кочагында бии» дигән мәкаләсе чыкты. Мәкаләдә төрле карашларга урын бирелсә дә, тулаем алганда, аңа объективсызлык хас. Беренче чиратта автор татар халкының тарихын бозып, аңа карата ихтирамсызлык күрсәтә. Автор раславынча, хәзерге территорияне татарлар моннан 500 еллар элек яулап алганнар һәм аннан соң ислам динен кабул иткәннәр. Чыганаклардан һәм археологик мәгълүматлардан күренгәнчә, татарларның ата-бабалары Идел буена ким дигәндә IV гасырда күчеп утыра башлаганнар, ә 922 елда, ислам кабул ителгәннән соң, куәтле Болгар ханлыгы барлыкка килгән һәм аны Казан татарларының беренче дәүләте дип санарга мөмкин. Ярый, автор тарихны белмәсен дә ди, әмма аның, имеш, Татарстан Президенты «Республиканы реформалардан сакларга» маташа, имеш, Татарстан Республикасының экономикасы «алга ыргылган Русия реформаларыннан» артта кала, дип язуы гаҗәпләнү уята. Ни өчен әле Русия реформалары эталон булырга тиеш? Миңа, мәсәлән, алар хаосны хәтерләтә. Сүз уңаеннан, бу хаоста «шок терапиясе» тәкъдим иткән Америка киңәшчеләренең дә өлеше зур. Нәрсә, Татарстанның реформаларга үз юлы белән, үз халкы мәнфәгатьләренә җавап биргән юл белән барырга хакы юкмыни? Әллә бөтен дөньяда Мәскәү тарафыннан тәкъдим ителгән бер генә юл бармы? Ниһаять, Татарстанның реформаларга каршы корылган курсы «Мәскәүдән тартып алган вәкаләтләрнең зур өлешен үз кулында тотарга мөмкинлек бирә» дип раслау иң гади нәрсәләрне дә аңламау дигән сүз. Реформаларга каршы бару түгел, ә, киресенчә, реформаларның уңыш китерүе республикага вәкаләтләрне кулында тотарга мөмкинлек бирә.

Татарстан үз эчке һәм тышкы политикасын эшли. Ул бөтен өлкәдә дә Русиянеке белән туры килми. Әмма бу әле без реформаларга каршы дигән сүз түгел. Без демократиягә һәм базарга үз юлыбыз белән барабыз. Кайсы юлның нәтиҗәлерәк булуын вакыт күрсәтер.

Бәхеткә, Америка матбугатында бүген башка төрле караш өстенлек итә. Анда чечен конфликтын һәм башка конфликтларны җайга салганда «Татарстан моделен» куллану мәсьәләсе тикшерелә. Сәяси фикерләрнең танылган үзәге — Гарвард университетында М.Шәймиев чыгышыннан соң Татарстанга карата кызыксыну уянуы, «Гаага инициативасы» идеясе дә шунда ук туды.

## II. «Гаага инициативасы»

14 — 15 гыйнварда тыныч Гааганың мәһабәт Тынычлык Сараенда элеккеге СССР җирлегендә барлыкка килгән дәүләтләрнең башлыклары һәм вәкилләре үзләрен борчыган проблемалар турында сөйләшер өчен җыелдылар. Грузия, Абхазия, Украина, Кырым, Молдова, Приднестровье, Гагаузия, Русия, Татарстан — бу республикаларны санап чыгу гына да хәтердә кайнар бәхәсләр, митинглар, сугыш хәрәкәтләре, корбаннар, ә аннан озакка сузылган һәм авыр сөйләшүләрне яңарта. Дубоссардагы, Сухумидагы сугыш хәлләренең үсешен, Татарстандагы референдумны, Кырымдагы сайлауларны бөтен дөнья киеренкелек белән күзәтте.

Мин дәүләт телләре турындагы мәсьәлә буенча безнең республикада барган бәхәсләрне искә төшерәм. Шушы ук вакытта шундый ук процесслар Молдовада да барды. Архивта төрле республикаларның телләре турындагы проектлар һәм законнар әле дә саклана. Молдаваннар бер генә телне дәүләт теле дип игълан итү белән, сәяси киеренкелек көчәеп китте. Аннан сәяси мәйданга Румыния белән берләшүне алга сөргән көчләр килеп чыкты һәм Молдова тәмам таркалды — сәяси картада өч дәүләт телле (молдован, украин, урыс) Приднестровье һәм молдован, гагауз, урыс телле Гагаузия пәйда булды. Кайнар бәхәсләр низагларга әверелеп китте, кешеләр корал телендә сөйләшә башладылар, кан түгелде...

Татарстанда ике дәүләт теле кабул ителде, ә суверенитет этник принцип буенча төзелмәде — тарихта катнашучылар республиканың бөтен халкы булды. Шулай итеп киеренкелек бетерелде... Бездән бик еш кына: ни өчен Татарстан үзен федераль хөкүмәт белән тиң куеп, ышанычлы рәвештә сөйләшүләр алып бара һәм Шартнамә төзи алды? дип сорыйлар. Аның бит тышкы чикләре юк, ул үз армиясен төземәде, ә республика составында татарларның нибары 25 проценты гына яши, диләр. Хикмәт шунда, республика җитәкчелеге позициясен халык яклап чыкты. Сөйләшүләр вакытында халык фикере таяну ноктасына әверелде. Ничектер бервакыт Мәскәүдәге югары түрәләрнең берсе халыкның төрле катламнарының республика җитәкчелегенә мөнәсәбәтен махсус рәвештә тикшергәнлекләрен таныган иде. «Нәрсә эшлисең инде алар белән!» — дип түгәрәкләде ул сүзен. Урыслар да, татарлар да Шәймиевне яклыйлар.

Күп кенә кешеләр сәясәтчеләр кабул ителгән законнарга һәм декларацияләргә, халыкара йөкләмәләргә һәм Конституциягә таянып эш итәләр дип саныйлар. Кызганычка каршы, бу фикердә хилафлык бар. Русия

делегациясе белән сөйләшүләр вакытында моның шулай булуына күп тапкырлар инанырга туры килде. Сәясәтчеләр үз мәнфәгатьләреннән чыгып һәм контрагентларның көче белән исәпләшеп эш итәләр. Ә инде шуннан соң юристлар нәтиҗәне «йотып булырлык» рәвешкә китерәләр. Элек-электән хокукка түгел, ә көчкә һәм башбаштаклыкка йөз тотып эш иткән Русия сәяси культурасына бу бигрәк тә хас нәрсә. Русия белән мөнәсәбәтләрдә Татарстанның көче аның халкының бердәмлегендә булды һәм шулай булып кала.

Милли проблемаларны уңышлы хәл итү мисаллары бөтен дөньясында бармак белән генә санарлык. Яшь дәүләтләрнең күпчелеге авыр конфликтлар уты аша узды. 1993 елның көзендә Казанга милләтара мөнәсәбәтләр буенча иң яхшы Көнбатыш экспертларының берсе Дюк (АКШ) университеты профессоры Дональд Хоровиц килде. Татарстанда җитди конфликт өлгереп килүенә ул аз гына да шикләнми иде. Икегә аерылган җәмгыять бөтен дөньяда һәр адымда диярлек күзәтелә, диде ул, килеп төшкәч, бердәнбер искәрмә бары тик Швейцариядә генә, бу илдә йөз ел буе халыклар бер-берсенә түзеп яшиләр, һәм биредә иң камил законнар. Казанда профессор республика җитәкчеләре, партия лидерлары, чиркәү һәм мәчет әһелләре белән сөйләште, урамда үткән-сүткән кешеләрне туктатып, аларга төрледән-төрле сораулар бирде, җәмгыятьнең икегә аерыла башлавын раслаучы билгеләр табар өчен җан-фәрман тырышты. Чиркәүдә аның белән мәзәккә тартым хәл килеп чыкты. «Христианнар белән мөселманнар арасында нинди каршылыклар бар?» дигән сорауга чиркәү әһеле аңа шактый кырыс тавыш белән: «Мөселманнар белән каршылыклар юк, әмма Америкадан килеп вәгазь сөйләп йөрүчеләр белән бар»,— дип җавап бирде. Китәр алдыннан Д.Хоровиц Татарстанда «кызыклы тәҗрибә» үткәрелүен танырга мәҗбүр булды. Безнең республикадагы хәлне өйрәнү аңа Русия чынбарлыгы үзенчәлекләрен аңларга да ярдәм итте. Халыкара форумнарның берсендә ул американнарга «АКШ федерализмы үрнәген Русия җирлегенә күчерергә маташу ялгыш адым» дип белдерде. «Аларның тарихлары бүтән»,— диде ул. Үз сәяси эшчәнлегебезгә читтән карарга безгә вакыт җитми, без аны тарихи тәҗрибә буларак кабул итмибез, ә бит бу тәҗрибә кемнәргәдер конфликтларны булдырмый калырга ярдәм итә алыр иде. Шуңа күрә микән, элеккеге СССРның күп кенә республикалары, шулай ук халыкара оешмалар һәм экспертлар безнең Гаагада түгәрәк өстәл үткәрү турындагы инициативабызга хуплап кушылдылар. Дөньяда конфликтсыз үсешнең уңышлы тәҗрибәләре бармак белән генә санарлык, шуңа күрә аларны игътибар белән өйрәнергә кирәк.

«Юләрне үз хаталары, акыллыны кеше хаталары өйрәтә...»

Кырым. Ул кемнеке? Берәүләр әйтә: ул — Украинаның бер өлеше һәм территориянең бөтенлеге кагылышсыз, ди. Икенчеләр, Кырымны Украинага тапшыру гадел булмаган, шуңа күрә ул Русиянең бер өлеше, дип раслый. Шушы бәхәсләр вакытында Кырым татарлары гына түгел, тулаем Кырым халкы да игътибардан төшеп кала. Әйе, Кырым — Украинаның бер өлеше, әйе, Русиянең бер өлеше булган, чөнки кайчандыр аны Русия яулап алган, ә аңа кадәр ул Кырым ханлыгы дип йөртелгән. Политик тормышта бу позицияләрнең барысы да бар. Шул ук вакытта Кырым татарлары — кайчандыр сөрелеп тә әле тулысынча туган илләренә кире кайтарылмаган һәм «тарихи гаделлеккә» исәп тотучы төп халык тәшкил итә, һәм алар артында зур энергетик һәм хәрби куәткә ия булган Русия тора, ә украиннар «территория бөтенлеге» принцибына таяналар. Әмма бит бу кешеләргә бергә яшисе һәм аларның бәхетле тормышының төп чыганагы Русия яки Украина түгел, ә үз җирләре. Төрле этник группаларның мәнфәгатьләре балансына нигезләнгән гражданлык җәмгыяте төземи торып, Кырымда сәяси тотрыклылык һәм аның чәчәк атуы турында сөйләү мөмкин түгел.

Биредә Татарстан тәҗрибәсе үзәк белән үзара мөнәсәбәтләрне җайга салуның моделе булмаган очракта, һич югы, башлап җибәрү ноктасы була алыр иде. Татарстан моделе аерым килешү төзү юлы белән һәм дәүләт төзелешен үзгәртүсез Кырымның статусын күтәрергә һәм сәяси киеренкелекне бетерүдән тыш, Киевның икътисади проблемаларының бер өлешен хәл итәргә мөмкинлек бирә. Сүз уңаеннан, Испаниядә «федеральләштерүне» нәкъ менә аерым килешүләр төзүдән һәм референдумнар үткәрүдән башладылар, бары тик шуннан соң гына 17 провинциягә автономия бирделәр. Мөнәсәбәтләрне килешүләр аша хәл итү Молдова — Приднестровье һәм Грузия — Абхазия конфликтларын җайга салу өчен дә бердәнбер сугышсыз юл. Андагы хәлләр Татарстандагы яки Кырымдагы хәлләрдән нык аерыла. Фактта сүз мөстәкыйль дәүләтләрне бергә кушу турында бара. Әмма биредә иң әһәмиятлесе принципны сайлый белүдә. Ассоциацияләштерелгән мөнәсәбәтләр урнаштыру вәкаләтләрне үзәккә яки нинди дә булса уртак органга бирүне ипле хәл итү мөмкинлеге тудыра, шул ук вакытта Абхазия белән Приднестровьеның суверенитеты сакланып кала, ә Грузия белән Молдованың дәүләт бөтенлеге таркалмый.

Конфликтны бетерү өчен сөйләшүне ике як өчен дә гомуми һәм кабул итәрлек булган нәрсәдән башларга кирәк. Проблемаларның бөтен комплексын тоташтан хәл итәргә омтылырга кирәкми. Хәлләр яхшыра барган саен, мөнәсәбәтләр дә шул ук килешү нигезендә тыгызлана башларга мөмкин.

Русия матбугатында ассимметрик мөнәсәбәтләр тәнкыйть ителә, янәсе, бу Русияне таркалуга алып бара. Ләкин үзегез уйлап карагыз, элеккеге СССРга һәм хәзерге Русиягә хас булган этник, географик, клима-

тик, экономик күптөрлелекне симметрик федератив мөнәсәбәтләр кысаларына ничек сыйдырып бетермәк кирәк. Бу һич мөмкин эш түгел. Бөтен кешене бертөрле яшәргә бары тик көч белән генә мәҗбүр итәргә мөмкин. Ә моның исә бернинди зарурлыгы юк.

Дөньяның күп кенә илләрендә ассимметриялелек норма буларак яши һәм ул беркемне дә өркетми. Күпләр, бәлки, белмидер дә, Германиядә Бавария белән Саксония үзләренең конституцияләрендә «җирләр» дип түгел, ә «ирекле дәүләтләр» дип аталалар һәм күп кенә халыкара йөкләмәләрне мөстәкыйль рәвештә башкаралар. Дания составындагы Гренландия шулкадәр киң хокукларга ия ки, хәтта ул Европа Союзына керүдән баш тартты, ә бит югыйсә Дания аның тулы хокуклы әгъзасы булып тора.

Этник һәм мәдәни аерымлыклар җирлегендә туган һәм яшәп килүче конфликтлар булган барлык илләрдә ассимметриялелек котылгысыз. Кырымның үз тарихы һәм аның халкының этник составы үзенә бер, шуңа күрә политик статус та котылгысыз рәвештә үзенчәлекле булачак. Абхазия белән дә шушындый ук хәл. Ул мөстәкыйль дәүләт буларак яши һәм, әлбәттә, Грузиянең провинциясенә әйләнергә ризалык бирмәячәк. Хәтта аерым статус белән кызыктырсалар да. Аңа ныклы гарантияләр кирәк. Үз валютасын чыгаручы, бәйсез дәүләт структуралары булган Приднестровье белән дә шушындыйрак хәл. Минемчә, ассимметриялелек кайдадыр күчеш стадиясе, ә кайдадыр тормышның күпкырлылыгын чагылдыручы норма да була ала. Кайсы гына очракта да бу аномалия түгел.

Грузиннар һәм абхазлар тарихка, конституциягә һәм халыкара хокукка ишарә ясап, һәркайсы ярсый-ярсый үзләренең хаклы булуларын исбатлыйлар. Бөтен бәла шунда — тегеләре дә, болары да хаклы. Русия ягы белән сөйләшүләр вакытында Татарстан делегациясенә прагматизм һәм центризм ярдәм итте. Мәскәүнең һәр аргументына Казанның контраргументы бар иде һәм киресенчә. Безгә, бер чиктән икенче чиккә ташланулар турында онытып, алга төп максат итеп республиканың тормыш мәнфәгатьләрен куярга кирәк булды. Аек акыл күзлегеннән караганда, мондый позиция бик яхшы аңлашыла, әмма яшәп килгән күпсанлы стереотиплар аркасында аны практикада гамәлгә ашыру авыр.

Сөйләшүләрне уңышлы алып бару өчен сәяси ихтыяр көче булу бик зарури нәрсә. Татарстан республикасын килешүне төзергә кирәк дигән кайнар теләк кенә рухландырмады, аның өч ел дәвамында үзгәрешсез диярлек эшләгән бердәм командасы да бар иде. Бу вакыт эчендә Русия делегациясе белән кемнәр генә җитәкчелек итмәде: Бурбулис, Тишков, Шахрай, Яров һәм, ниһаять, Ельцин. Составы даими рәвештә үзгәреп торган Русия делегациясе белән чагыштырганда, безнең өстенлек зуррак иде. Чөнки дәвамчанлык сәяси мәсьәләләрне тирәнтен өйрәнергә һәм катлаулы бәхәсләр алып бару тәҗрибәсе тупларга мөмкинлек бирде. Сөйләшүләрнең уңышлы төгәлләнүе аларның төрле югарылыкта: иң югары дәрәҗәдә, хөкүмәтләр һәм министрлыклар дәрәҗәсендә алып барылуы белән дә аңлатыла.

Гаагага без ни өчен җыйналдык? Чөнки безне үткәннәр берләштерә һәм безнең өстән әле һаман да империя традицияләре йөге төшмәгән. Үз вакытында А.Сахаров СССР дигән бер империя урынында күпсанлы вак империяләр барлыкка килергә мөмкин дип кисәткән иде. Сәяси проблемаларны көч белән хәл итү теләгеннән котылу һәм барлык халыкларның ирекле үсәргә лаек булуын таныр өчен вакыт кирәк. Көчләү көчләү тудыра. Азатлык аша ышаныч килә.

Кызганычка каршы, элеккеге СССР киңлекләрендәге барлык илләр дә әгәр дәүләт вәкаләтләренең бер өлешен үзәктән урыннарга тапшырса, ул хәлсезләнә дигән ялгыш фикер яши. Халык таләбенә «юл куюны» күп кенә җитәкчеләр үзләре өчен зур түбәнчелек саный. Шул ук вакытта дөнья тәҗрибәсе моның киресен раслый. Татарстан белән килешү төзү нәтиҗәсендә Мәскәү күп кенә вәкаләтләрен Казанга тапшырса да, бу Русиядә сәяси кризис тудырмады. Алай гына да түгел, ул федераль хөкүмәтнең абруен күтәрде. Шул ук вакытта Чечня хәлләре Мәскәүдәге тотрыклылыкны какшатты, Русиянең бөтенлеге турындагы мәсьәләне тагын көн тәртибенә күтәрде һәм бөтен дөньяны империя яңадан әйләнеп кайта бугай дигән курку алдында калдырды.

Ни өчен Татарстан үзенең халыкара политикасын алып барырга тиеш, ни өчен без «Гаага инициативасы» кебек башлангычлар белән чыгабыз?

Беренче чиратта безне Татарстанның статусын һәм аның Русия белән урнаштырылган мөнәсәбәтләрен тануларын кызыксындыра. Мәскәү җитәкчеләренең кыйблалары үзгәреп тору безнең киләчәктәге ике яклы мөнәсәбәтләргә йогынты ясарга тиеш түгел. Нәкъ менә шуның өчен безгә халыкара яклау кирәк. Практикадан күренгәнчә, халыкара җәмәгатьчелек фикере Русия җитәкчелегенең үз-үзен тотышына тәэсир ясаучы фактор булып тора. «Гаага инициативасы»ннан соң Көнбатышта игътибарны Татарстанның тынычлык политикасына юнәлткән мәкаләләр күренде. БМО Генераль секретаре Бутрос Гали бу оешманың Куркынычсызлык советына яңа инициатива турында мәгълүмат бирүне кирәк дип тапты һәм М.Шәймиев белән шәхси очрашу вакытында аңа рәхмәт белдерде. Боларның барысын да, билгеле, Мәскәү күрми калмады.

Тагын шуны әйтергә кирәк: тынычлык инициативалары республиканың уңай имиджын тудыра һәм икътисади хезмәттәшлекнең тагын да активлашуына (ә моннан башка дөнья базарына керү мөмкин түгел) ярдәм итә. Һәм, ниһаять, мондый сәясәт империячел көчләргә киртә куярга мөмкинлек бирә.

«Гаага инициативасы» элеккеге СССР җирлегендәге дәүләтләрдә вакыйгаларның конфликтсыз үсүен тәэмин итү юлларын булдыру буенча зур һәм мәшәкатьле эшнең башы гына. «Татарстан моделе» дигән термин бүген шактый еш телгә алынуга да карамастан, ул әле ахыргача эшләнеп бетмәгән. Татарстан җәмгыятенең икътисади, социаль һәм мәдәни үсеше күзлегеннән караганда, «Татарстан моделе»нең нәрсә аңлатканын, дөнья базарына республиканың ничек керәчәген һәм дөнья культурасында аның урыны нинди булачагын без әле ачыклап бетермәдек.

## III. «Татарстан моделе» — яңа үрнәк

Суверенитет идеясе Татарстанда 1990 елдан башлап иҗтимагый аңны биләп алган идеягә әйләнде. Бу мәсьәләдә битарафлар аз иде. Суверенитет тарафдарларын да, аңа каршы чыгучыларны да шушы идея бимазалады: берәүләр аны яклады, ә берәүләр аңа каршы көрәште. Татарстан белән Русия килешүендә әлеге идея хокукый яктан ныгытылды һәм, үзенең элеккеге яңгырашын югалтып, эшли башлаучы категориягә әверелде.

Килешүгә кул куелганнан соң, иҗтимагый тормыш акцентлары да урыннарын үзгәртте. 1994 елга кадәр сәясәт башка проблемалардан өстенлеклерәк урынга куелса, бүген беренче планга икътисад чыга. Моңа промышленностьның гомуми хәле начараю һәм кешеләрнең тормыш шартлары түбәнгә тәгәрәү дә этәргеч бирде. Кыскача әйткәндә, без сәяси тотрыклылык проблемасын хәл иттек һәм хәзер көн тәртибендә экономик тотрыклылык мәсьәләләре тора.

Тарихта инде күп тапкырлар күзәтергә туры килгәне бар. Бу юлы да Русия сәяси яктан ныгытылмаган һәм җәмәгатьчелек фикерен әзерләмәгән килеш бер селтәнүдә — «шок терапиясе» ысулы белән — бөтен экономиканы дөнья дәрәҗәсенә чыгарырга ыргылып карады. Тисә — тиенгә, тимәсә — куянга дигән сыман, киңәшчеләрнең дөрес булмаган тәкъдимнәренә таянып, «реформаторлар» илне шундый кысаларга куып керттеләр ки, алга бару хәрәкәте тыгылды, ә кирегә чигенү сәяси тетрәнүләрдән башка мөмкин түгел. Реформалар үткәрү өчен Русиядә тиешле сәяси тотрыклылык юк, ә лидерларны исә экономик мәсьәләләрдән битәр, 1996 елда яңа президент сайлау проблемалары кызыксындыра. Проблеманы тагын шул нәрсә катлауландыра: булачак сайлауларда яңадан баш калкыткан «сул» коммунистик көчләр өстенлек итәчәк һәм аларның «дәүләт экономиканы үз контроле астына алырга тиеш» дигән таләп белән чыгачагы шик тудырмый. Шулай итеп, ил үзәкләштерелгән экономикадан базар экономикасына күчү юлында, ягъни урталыкта асылынып калачак.

Татарстан Республикасында «шок терапиясе»ннән баш тарту сәяси яктан акланган карар иде, әмма без бу адымның өстенлекләреннән файдалана белмәдек. Нәтиҗәдә, Татарстан бөтен күрсәткечләр буенча да зур тизлек белән Русиягә хас хәлләргә якынайды, ә тормыш өчен әһәмиятле кайбер базар инфраструктураларын (мәсәлән, финанс-банк структураларын) үстерүдә артта калды. Моның сәбәбе бик гади — стратегиянең булмавы. Министрлыклар һәм ведомстволарның ду килеп кайнашулары бердәм максатка юнәлдерелмәгән иде, ә социаль гаделлек категориясе экономик үсеш идеясенә буйсындырылмады.

Әлбәттә, халыкны якларга кирәк. Ләкин моны тормышка ашыру юллары төрлечә булырга мөмкин. Казнадагы акчаны авыр хәлдә яшәүчеләргә һәм эшсезләргә ярдәм итү өчен бүлгәләргә мөмкин, ә икенче яктан, эш урыннары булдыру һәм җитештерүгә җан өрү белән шөгыльләнергә була. Беренче очракта — бюджетка басым ясала һәм хөкүмәттә налогларны арттыру теләге уяна, нәтиҗәдә җитештерү кими. Әгәр инде дәүләт яңа эш урыннары булдыруга (әйтик, хезмәт күрсәтү өлкәсендә, биредә гаять зур резервлар бар) этәргеч бирсә, шуның белән ул үзен күп кенә социаль проблемаларны чишүдән азат итә. Чыннан да, акчаны үзе эшләп тапкан кеше дәүләт ярдәменә мохтаҗ түгел, моннан тыш ул әле үзе дә якын туганнарын тәрбияли ала. Дөрес, бу очракта җитештерүчеләр өчен салымнарны йомшарту таләп ителә. Әгәр бүген бюджетның төрле яклап йолкынуын, ә налогларның түшәмгә менеп җитүен исәпкә алсак, республика өчен бер генә юл кала: бу товар җитештерүчеләрне кызыксындыру.

Татарстанның экономик зиһенләү рәвеше куандырырлык «җимешләр» бирмәде. «Үзгәртеп кору» башында ул төрледән-төрле башлангычлар белән чыкты һәм күпләрне республикадагы экономик хәлнең үзенчәлеге турында уйларга мәҗбүр итте. Ләкин соңыннан болар барысы да беркемне дә диярлек кызыксындырмаган ялыктыргыч һәм күңелсез телевизион тапшырулар һәм мәкаләләр белән түгәрәкләнде. Сайлау алды кампаниясе депутатларның арсеналында экономик идеяләрнең булмавын күрсәтте, ә бу җәмгыять тормышында экономистларның роле төшүе турында сөйли. Алай гына да түгел, безнең галимнәр экономик

кризистан чыгу юлын күрсәтмәделәр генә түгел, ә җәмәгатьчелекне хәтта башка илләр тәҗрибәсе белән дә таныштырмадылар. Нәтиҗәдә, без көннән-көн үсә барган проблемаларны урыннарыннан кузгата алмаслык мескенлектә калдык, ә төрле программалар эшләү буенча хөкүмәт комиссияләре, гомуми экономик идеология булмау сәбәпле, кыйблаларын югалттылар.

Федераль җитәкчелекне сепаратизм белән (каян килсен инде ул) өркетүдән куркып, Татарстанда көнләшерлек үҗәтлек белән, без Русия белән бердәм экономик киңлектә, дип тәкрарлап килделәр. Ышанычлы эчке базар дип, предприятиеләр Русия белән БДБга йөз тотты, ә бу базар исә берничек тә яклanмаган булып чыкты һәм дөнья базарының бер өлешенә әверелде. Көнбатыш фирмалары яңа шартларга тиз арада җайлашып, үзләренең товарларын күпләп ташый башладылар, актив реклама эшчәнлеге, сервис һ.б.ларны киң җәелдерделәр. Ә безнең предприятиеләрнең күпчелеге банкротлык чигенә килеп җитте.

Шулай итеп, дөнья базары безнең өйгә килеп керде, һәм әлеге дә баягы «Русиянең бердәм экономик киңлеген» кабып йотты, ә без үзебез дөнья базарына чыга алмадык, һәм талымсыз эчке ихтыяҗ яшәп килгәндә үтмәс товарлар да үтәр әле дигән өмет белән бу базарга чыгарга әллә ни атлыгып та тормадык. Ә эчке базар бик мәкерле нәрсә булып чыкты. Безнең илдә җитештерелгән телевизорларны, көнкүреш техникасын, косметиканы һ.б. бүген кемнәр генә ала икән?

Яңа үрнәкнең төп мәгънәсе дөньякүләм экономик һәм культура киңлегенә йөз белән борылудан гыйбарәт.

Татарстан — дөньяның аерылгысыз өлеше һәм безнең аңыбыз, ә иң мөһиме, реаль экономик һәм башка төрле мөнәсәбәтләребез дөнья культурасы таләпләренә тәңгәл килергә тиеш. Тимер чаршау гамәлдә булган чорда без СССРның йомык түгәрәге эчендә яшәдек һәм бөтен экономика өстән — Госпланнан көйләнә иде. Базар мөнәсәбәтләренә күчү, тышкы сәүдәне һәм политик системаны иреккә чыгару нәтиҗәсендә без ачык җәмгыятькә әверелә барабыз. Фактик мөнәсәбәтләр үзгәрде, ә фикерләү рәвеше элеккечә калды. Без әле һаман да Татарстан яки Русия базары күзлегеннән чыгып фикер йөртәбез һәм дөньяда бүтән киңлекләр дә булганлыгын күрмибез. «Өлкәчә уйлау» әле һаман өстенлек итә һәм экономиканың аска тәгәрәвенә китерүче төп сәбәпләрнең берсе булып тора.

Республика дистә еллар дәвамында нефть химиясен үстерү лозунглары белән яшәде. Татарстанны башта икенче Баку дип, аннан икенче Кувейт дип атадылар. Әлеге мәсьәләләргә дөнья тенденцияләре күзлегеннән карап карыйк. Иң беренче күзгә ташланган нәрсә шул: алга киткән илләр нефть белән түгел, ә катлаулы эшләнмәләр, технологияләр һәм белемнәр белән сәүдә итә. Алар чимал ресурсларын сатып алалар һәм югары технологияле продукция саталар, шул ук вакытта фәнне һәм мәгариф системасын үстерүгә акча кертәләр. Кешеләрнең квалификациясен күтәрү зыян китерми торган бердәнбер өлкә дип санала. Бай илләр ни өчен бай? Төп юнәлешләрдә фәнни мәктәпләрен үстергәнгә, эшчеләргә югары хезмәт хакы түләгәнгә һәм кешеләрнең яшәү рәвешен югары дәрәҗәдә тотканга.

Чимал белән артта калган илләр сәүдә итә. Алар ришвәтчелек, җинаятьчелек, сәяси тотрыксызлык һәм әледән-әле чыгып торган коралны низаглар чолганышында яшиләр. Нефть илләре эшчеләргә түбән хезмәт хакы түләү хисабына яши, Кувейтның чәчәк атуының нигезендә, кызганычка каршы, эмигрантларның арзанлы эшче көченнән файдалану ята.

Кайчандыр артта калган илләр дип саналган Көньяк Корея, Тайвань, Сингапур мисалына тукталып үтик. Бу дәүләтләрнең уңышка ирешүенең сере нәрсәдә, аларның чимал чыганаклары юк бит? Моннан утыз ел элек Көньяк Корея хәерче ил иде. Моннан нибары унбиш ел гына элек Сингапур берни дә җитештерми иде, ә бүген дөньядагы барлык компьютерлар Сингапур дисклары белән тәэмин ителә. Барлык илләрнең кибет киштәләрендә Тайвань продукциясе өелеп ята. Бу илләр артыннан дөнья базарына Малайзия, Индонезия, Гонгконг чыгып килә. Аларның чәчәк атуының берничә төп сәбәбе бар. Бу илләр дөньяда иң талымчан кулланучыга йөз тоттылар, алар көчләрен төрле якка чәчмичә, тырышлыкларын берничә катлаулы әйбер җитештерүгә юнәлдерделәр. Һәм, ниһаять, алар мәгърифәткә һәм заманча технологияләр сатып алуга акчаларын кызганмадылар: «Сникерс»лар һәм «Баунти»ларга сарыф итмичә, алар валюталарын халыкара бизнес үзәкләрендә яшьләрне әзерләүгә тоттылар һәм заманча технологияләргә лицензияләр сатып алдылар. Татарстан нәрсәгә исәп тота ала? Продукциянең бәясе түбән булугамы? Кытайда барыбер арзанрак булачак. Югары сыйфатлы продукциягәме? Аяк киемнәре җитештерүдә итальяннарның борынына чиртеп булмаячак, электрониканы «Азия юлбарысларыннан» яхшырак ясау, ай-һай, икеле. Компьютерларны американнардан да яхшырак эшләп чыгару, ә автомобильләр җитештерү мәсьәләсендә немецлардан уздыру мөмкин түгел. Димәк, бер генә юл кала: бу — хәтта кытайлар да җитештерә алмаган катлаулы продукция җитештерү. Бу продукция Европадагыга караганда да арзанрак булырга тиеш. Әлеге стратегияне күчеш стратегиясе дип карарга кирәк. Дөнья базарында безнең урын ачыкланганга кадәр һәм товарлар конкурентлык сәләтенә ия булганчы шушы юнәлешне тотарга кирәк.

Нефть кебек чимал булу безгә өстенлек бирергә мөмкин. Ләкин моның өчен без аны эшкәртергә һәм әзер продукция сыйфатында сатарга тиеш. Мисал өчен, шиннар яки «КамАЗ» автомобильләре өчен башка төрле әйберләр, ә киләчәктә Алабуга автомобиль заводы автомобильләре өчен кирәкле әйберләр сыйфатында. Нефть химиясе комплексының куәтле, ә Казандагы химия фәнни мәктәбенең көчле булуы бу юнәлешнең өметле һәм өстенлекле икәнен раслый.

Товарларның конкурентлык сәләтен күтәрергә Татарстандагы төрледән-төрле экономик тармакларның бер-берсенә гомуми «идеология» базасында бәйләнгән булуы ярдәм итә. КамАЗга гына түгел, машина төзү комплексының башка эре предприятиеләренә дә үзләренең заказларын Татарстан территориясендә урнаштыру максатка ярашлы булыр иде.

Республика хөкүмәтенә Татарстаннан чыккан товарларның башкаларга конкурент була алуын стимуллаштыру мәсьәләсендә юнәлешләр билгеләү гаять әһәмиятле. Бу әһәмиятлелек озак сроклы стратегия юнәлешләреннән караганда гына түгел, ә агымдагы бурычлардан чыгып эш иткәндә дә гаять зарури.

Республиканың конкуренциягә сәләтен күтәрү аның гомумдөнья стандартларына җайлашуын таләп итә. Телисеңме, теләмисеңме, Көнбатыштагы фикерләү рәвешенә һәм Көнбатыш культурасына ориентлашырга туры киләчәк. Бу үз чиратында милли традицияләрне юкка чыгаруга китермәсме? Хаклы рәвештә әнә шундый сорау туарга мөмкин. Әлбәттә, дөньяда танылган кайбер стандартларны кабул итәргә туры киләчәк. Әмма Татарстан дөнья базарында үзенең урынын тарихи традицияләр һәм милли үзенчәлекләрдән мөмкин кадәр тулырак файдаланган очракта гына яулап алачак.

Австриядә булганда мин шуңа шаккаттым: карап торышка әллә ни зур булмаган илдә милли генә түгел, ә региональ гадәтләр дә саклана. Зальцбургта, мәсәлән, бөтен җирдә Моцарт рухы. Һәр тарафта сиңа аның күзләре карый. Олысы-кечесе аны җырлый, уйный һәм һәр адымда аның сурәте төшерелгән сувенирлар сатып алырга мөмкин. Бөек исемне үзенчәлекле «эксплуатацияләү» бара һәм Зальцбург җире өчен шуннан да яхшы реклама юк.

Чит ил кешеләре миңа еш кына сорау бирә: «Шаляпин Казанда туган дигән сүз дөресме? Ә ул туган йортны карарга мөмкинме? Сувенирлар сатып алу мәсьәләсе ничек?» Казанга килгән һәр чит ил кунагының истәлеккә нәрсә дә булса эләктереп китәсе килә. Университетта Лобачевскийның эшләвен, ә Толстойның биредә укуын, Шаляпинның Казанда җырлый башлавын белгәннән соң, аларда Татарстанга карата хөрмәт хисе уяна. Мөселман илләреннән килгән кунакларны үзенең демократиклыгы белән аерылып торган җәдидлек фәлсәфәсе таң калдыра. Ә без исә, аларның республика турында күбрәк белергә теләү ихтыяҗына җавап итеп, «Адидас» майкалары һәм «Красная шапочка» кәнфитләре тәкъдим итәбез. Без Татарстан үзенчәлегенең кыйммәтле җәүһәр булуын әле һаман да аңламадык. Безнең өстенлекләр нефтьтә түгел, ә үзенчәлекле мәдәният, этник традицияләр һәм әхлак нормаларын дөньяга чыгаручы һәм яшәтүче кешеләрдә. «Татарстан моделе» турында фикер йөрткәндә, ирексездән бер сорау туа. Ярар, Татарстан экономиканы үстерүдә уңышларга иреште ди, ләкин бит ул рубль зонасы эчендә һәм иртәгә нәрсә тоҗырасы билгесез Русия сәясәтенә бәйле. Мондый тотрыксыз хәлләрдә стратегия турында гомумән сүз алып барырга мөмкинме соң?

Чыннан да, Мәскәүдә тотрыклылык һәм карарлар кабул итү мәсьәләсендә ачыклык булмаган бер вакытта экономик үсешне планлаштыру бик авыр. Шуңа да карамастан конкурентлык өстенлекләре региональ дәрәҗәдә төзелә. Экономик яктан алга киткән илдә артта калучы провинция булырга һәм шул ук рәвештә экономик яктан йомшак дәүләттә чәчәк атучы төбәк булырга мөмкин. Моңа мисаллар бихисап.

Экономика чәчәк атсын өчен, республика җитәкчелегенең политикасы ачык һәм эшкуарлар өчен аңлаешлы булырга, озак сроклы проектлар өчен мач килеп торырга тиеш.

1995 елның гыйнвар ахырында Стенфорд университеты (Калифорния) чакыруы буенча миңа Русиянең Федератив төзелешенә багышланган конференциядә чыгыш ясарга туры килде. АКШта иң шаккатырганы шул: биредә университет хезмәткәрләренә (гәрчә алар иң югары хезмәт хакы алмасалар да) зур ихтирам белән карыйлар. Сан-Францискода яшәүче татарлар белән очрашу мине аеруча тәэсирләндерде. Алар Американың махсус телевизион каналлары буенча М.Шәймиевнең Гарвард университетындагы чыгышының трансляцияләнүе турында горурланып сөйләделәр. Университетларның чыгыш ясарга яки уртак эштә катнашырга чакыруы Көнбатышта бик зур дәрәҗә санала.

Мин безнең республикада университетлар һәм институтларның әһәмиятен аңламау яши дигән фикердән ерак торам. Әмма Көнбатышта фәнне ихтирам итәләр, чөнки ул файда бирә. Безнең фән һәм мәгърифәт системасы бу дәрәҗәгә җитүдән әлегә ерак тора. Ләкин гаепләләрне эзләүдән файда булмас. Бу безнең уртак бәлабез, аннан чыгуның юлы бер генә — дәүләт, предприятиеләр һәм фән учреждениеләренең кулгакул тотынып эшләве.

Географик факторлар һәрвакыт геополитик хәлгә үзенчәлек кертә һәм моннан файда алу мөмкинлеге бирә. Татарстанга килсәк, ул төрледән-төрле — су, таш, тимер юллар һәм авиатрассалар чаты. Без Идел-Урал регионы уртасында урнашкан һәм моннан мөмкин кадәр зуррак экономик отыш алырга кирәк.

Татарстанның куәтле машина төзү комплексы, перспективалы фәнни базасы, күп профильле мәгариф системасы бар, ул югары квалификацияле кадрларга бай, һәм республика географик яктан отышлы урынга урнашкан. Болар барысы да киләчәк уңышының кушылучыларын тәшкил итә.

## ХОКУККА ХАК

әсәй конституцион кризис кичерә. Моның төп сәбәбе — милли-дәүләти төзелеш мәсьәләсенең хәл итүдән тайпылырга, үзәкләшүне көчәйтергә маташу. Бигрәк тә Чечня сугышын башлап җибәрү Русия дәүләт хакимиятенең зәгыйфьләнүенә һәм тулаем тотрыксызлыкка китерде.

Тарихи яктан Русия төрле ханлыклар, территорияләр һәм халыкларның конгломераты рәвешендә барлыкка килде. Кайчандыр урыслар тарафыннан яулап алынган яки Русиягә «ирекле рәвештә кушылган» халыклар бүген үзләренең тарихи ватаннарында оешкан хәлдә яшәп яталар һәм үзләренең элекке дәүләтчелеген хәтердә саклыйлар. Аларның үз-үзләрен тотышын башлыча этник мәнфәгатьләр билгели һәм бу аларның федеральләштерүне, анык милли сәясәт булдыруны таләп итүдә гәүдәләнә.

1917 елдан соң нәкъ менә урыс булмаган халыклар Русияне федерализм башлангычында үзгәртеп кору инициаторлары булдылар. Әмма совет хакимияте, илне патша Рәсәе белән чагыштырганда да бердәмрәк илгә әверелдереп, федерализм һәм милләтләрнең үзбилгеләнү идеяләрен тактик лозунг буларак файдаланды. Табигый ки, үзгәртеп кору башлану белән, халыклар үз хокуклары турында яңадан сүз кузгаттылар.

Русия күп халыклар өчен аларга үз мәдәниятен үстерә алырлык бердәнбер яссылык булып тора. Алар — төп халык. Чөнки үз территорияләрендә элек-электән, ягъни урыслар килгәнче үк яшәгәннәр. Шуңа күрә алар урыслар белән беррәттән дәүләт төзүче этнос булу роленә дәгъва итәләр. Русиянең дәүләт төзелеше анда яшәүче барлык халыкларның мәнфәгатьләренә нигезләнергә тиеш. Сәяси һәм этносара киеренкелектән котылуның бердәнбер юлы бу.

Русиянең күп төбәкләрендә урыс булмаган мөселман халкы арта һәм бервакыт урыслар белән чагыштыргысыз дәрәҗәдә үсәчәк. Төрле географик ландшафтлы Русия кебек шушындый зур илнең аерым төбәкләрендә урыс булмаган этнослар өлешенең шактый зур булуы җитди сәяси факторга әверелә.

Чечня сугышы сәяси чишелешләрдә аңа сан зурлыгыннан чыгып якын килүнең һәлакәткә китерүен раслады. Чечняда һәм аның тирәсендә 500 меңгә хәтле солдат тупланган иде. Шуңа карамастан сугыш оттырылды.

Чечня сугышы үзәк белән төбәкләр арасындагы мөнәсәбәтләр проблемасын катлауландырды. Беренчедән, ул чеченнарда гына түгел, барлык урыс булмаган халыкларда Русия җитәкчелегенә карата ышанмаучылык тудырды, Русия җитәкчелегенең демократлыгына өмет итәргә ярамаганны раслады. Мәскәүгә карата гасырлар буена яшәп килгән ышанмаучылык яңадан сәяси факторга әверелде. Икенчедән, Чечня мәсьәләсен хәл итү республикага аерым статус бирүне таләп итә. Мөгаен, монда «Татарстан моделе» яраксыздыр, чөнки Чечня статусы буенча теләсә кайсы Шартнамә РФ Конституциясе белән кискен каршылыкка керәчәк. Өченчедән, иминлек гарантияләре алу һәм торгызу эшләрен финанслау өчен Чечня үзенең халыкара эшчәнлеген активлаштыра, моның исә Русия һәм Кавказдагы тотрыксызлыкның өстәмә факторына әверелүе мөмкин.

Русиянең полиэтник составы мәгълүм сәяси чишелешләр таләп итә. Татарстанда без полиэтник, полимәдәни җәмгыять төзү концепциясен кабул иттек. Әмма Русиядә, аның Конституциясе преамбуласында күпмилләтле дәүләт принцибының игълан ителүенә карамастан, реаль процесслар моноэтник дәүләт концепциясенә туры килә.

Русиядә милли азчылыклар турында закон кабул итеп кенә чикләнеп булмаячак. Татар, башкорт, чуваш, якут һ.б.ларны милли азчылык дип кабул итеп булмаячак, алар үз территорияләреннән тыш та төп халык булып торалар. Шунысын да әйтергә кирәк, милли азчылыкларны яклау турында Аурупа конвенциясенә һәм төбәк телләре, азчылыкларның телләре турындагы Аурупа хартиясенә кушылырга кирәк.

Русия үзенең дәүләт сәясәтен полиэтник составка көйләргә мәҗбүр булачак. Моның өчен, бердән, эзлекле федеральләштерү, икенчедән, барлык халыкларның мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүче милли сәясәт эшләү, шушы сәясәтне тормышка ашыру механизмын эшләү зарур.

## КЕМ СИН, ТАТАР?

үңел тыныч түгел…

Татарларга бер әшәке сыйфат хас: төркемнәргә бүленеп бер-берсен ашау. Бу турыда күпләр язып чыкты. Мин дә, кеше язмышларының борылышларын күзәтә-күзәтә, үз-үземә сорау бирәм: нигә шулай? Татар милләтенең хәле болай да җиңел түгел ләбаса. Ни өчен өстәмә кыенлыклар китереп чыгарырга?

Казанда гына түгел, татар яшәгән теләсә нинди шәһәрдә, районда, авылда, янәсе, мөһим дип саналган мәсьәләләр тирәсендә вак-төяк ыгы-зыгы бара. Мәскәүгә барсаң, татарлар белән очрашу да күңелсез: берәүләр икенчеләренә пычрак ата, гел кемнедер каяндыр бәреп төшерү белән мәшгульләр, синең шуларны хуплавыңны өмет итәләр. Ә нәрсәне хупларга соң? Аңлашылмый. Шәхси амбицияләрнеме, кухня тирәсенә хас вак-төяк проблемаларнымы? Русиянең һәм БДБ илләренең башка шәһәрләрендә дә шулай ук — күпләр үз милләттәшләре белән көрәштә хакыйкать эзләп, яшь түгеп хатлар язалар.

Вак-төяк амбицияләр халык язмышыннан өстен була башлады.

Татарларның бер-берсенә каршы көрәшенә күпме көч китте, гәрчә бар каршылык «тегеләренең» бары тик башка оешмадан яки башка институттан, башка урамнан яки башка йорттан булуыннан гына гыйбарәт иде. «Безнең кеше» дигәндә татар кемне күзаллый икән соң алайса?

«Мирас» журналы Мирфатыйх Зәкиев белән бәхәс кузгатты, аны озак елларга сузып, суд юлларында йөрде. Символик күренеш. Без буыннан буынга мәдәниятебез мирасын гына түгел, ыгы-зыгыны да күчерәбез, ә ыгы-зыгы, мәгълүм ки, шайтан гамәле.

Русия Федерациясенең Конституция судына Татарстан Конституциясен гаепләгән дәгъваны әллә каян, әллә кем түгел, нәкъ менә үзебездә яшәгән үз татарыбыз — Азнакай районыннан Марсель Сәламов язып җибәрде. Ул үз республикасы һәм үз халкы белән судлашты. Аның татар булуы оят, минем әнием туып үскән районнан чыгуы оят.

Амбицияләр канәгатьләндерелде. Һәркем үз хакыйкатенә тугры калды. Күпме вакыт әрәм булды. Күпме көч юкка сарыф ителде.

Татарга мондый сыйфат каян килгән? Мин бу сорауга җавап таптым шикелле. Коллык психологиясеннән һәм мескенлектән. Күп гасырлар буе татарны бүлгәләп, берсенә-берсен өстереп идарә иттеләр. Мондый вазгыятьтә үз көчеңә ышанмый башлыйсың. Моны, бәлки, башкача да аңлатып буладыр?

Үз вакытында Столыпин татарларның һәрбер этник төркеменнән үз әдәби теле булган аерым халык ясарга тәкъдим иткән һәм шуның белән милләтне юкка чыгарырга ниятләгән.

Большевиклар бу сәясәтне уңышлы дәвам иттеләр. Картада үзбәкләр, кыргызлар барлыкка килде. Ашыгыч рәвештә башкорт теле һәм башка милли «кирәк-яраклар» уйлап табылды. Башкортларның визит карточкасы сыйфатында үзенчәлекле бер бию туды, анда егетләр төлке койрыгы таккан бүрекләр киеп бииләр. Әлеге биюне уйлап чыгарып сәхнәгә куючы Фәйзи Гаскәров — 60 нчы елларда, Казанда фатир ала алмаганга, Уфага күчеп киткән татар. Бу бию — сәхнә төзелмәсе. Халкы да нәкъ шулай оештырылган, әмма башка сәхнә — сәясәт сәхнәсе өчен.

Большевиклар эшне киң колач белән алып бардылар. Кавказ татарлары азәрбайҗаннарга гына түгел, кумыкларга, балкарларга, карачайларга әверелде. Иң мәшһүр шәхесләре — Казан патшабикәсе Сөембикә булган нугайлар мөстәкыйль халыкка әйләнделәр. Ә Сөембикәнең ире Сафа Гәрәй бөтенләй башка халык — Кырым татарлары вәкиле булып чыкты. Алайса, Казанда нишләп ятканнар соң алар? Казан татарлары бу «килмешәк»ләрнең хан тәхетендә утыруына ничек чыдап торган? Бу сорауга җавап бик гади: чынлыкта болар барысы да — Алтын Урда чорында оешкан бер халык. Татарлар Казанда, Әстерханда, Себердә, Касыймда, Кырымда, мишәр җирендә, нугай, башкорт далаларында һәм башка җирләрдә яшәгәннәр, шуңа күрә төрлечә аталганнар: Казан, Әстерхан, Себер татарлары, мишәрләр, Кырым татарлары, нугайлар һәм башкортлар. Себердә яшәүче урысларны «сибиряк» дип атыйлар, ләкин алардан аерым халык ясап «себер урыслары» дип атарга берәүнең дә башына килми. Әгәр дә этнографлар һәм сәясәтчеләр бераз тырышсалар, халыкны шулкадәр бутарга мөмкин ки, алар «без урыслар түгел, без — сибиряклар» дип әйтәчәк. Аларга себер милли киемнәре, биюләре, аерым сөйләш уйлап табачаклар. Һәм тагын бер милләт әзер дигән сүз.

Милли сәясәт нигезендә һәрвакыт ялган яткан.

Хәзер РФ хөкүмәте карары буенча нугайбәкләр аз санлы аерым халык булып санала, дөрес, алар хәзергә татарча сөйләшәләр. Инде берничә ел Себер татарларын һәм аларның аерым телен оештырып маташалар, моңа безнең галимнәр дә бик актив булыша. Сәясәтчеләр «керәшен» дигән мөстәкыйль халык уйлап таптылар. Аларны Русия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институты гына түгел, Милли мәсьәләләр комитеты аркылы Дәүләт Думасы да, Идел буе федераль округы да, хәтта Патриарх үзе дә яклый. Керәшеннәр керәшен телендә түгел, шул ук татар телендә сөйләшә, керәшен җырларын түгел,

шул ук татар җырларын җырлый, татарча бии. Керәшеннең тик православный диндә генә булган шул ук татар икәнлеге күзгә бәрелеп торса да, хәзер моны дәлилләү җиңел булмас. Асылда исә керәшеннәр — төп татарлар. Нәкъ менә керәшеннәрдә генә татар культурасының борынгы катламнары сакланган. Ә бит хәзер кемнәрдер керәшеннәрнең мөстәкыйль этнос була алачагына ышана да башлады. Ачык һәм мәгънәле максаты булмаган халык теләсә нинди абсурдны кабул итәчәк. Столыпин сәясәте тантана итә.

Күңелегезне киң тотыгыз — эш әле типтәрләргә, мишәрләргә, Әстерхан татарларына да барып җитәчәк. Яңа халыклар барлыгын заказ буенча игълан итүче активистлар да табарлар. 2002 елда халык санын алу өчен әзерләнгән милләтләр исемлегендә татарлардан тыш мишәрләр һәм Казан татарлары аерып куелган. Хәзер Казанда яшәп ятучы, әмма нәселендә мишәрләр булган татар үзенең кем икәнлеген билгеләр алдыннан бик каты уйланырга мәҗбүр. Кем ул: татармы, Казан татарымы яисә мишәрме? Этнология һәм антропология институты халыкларга теләгәнчә ялганлый, ә татарлар, бер сүз дәшмичә, барысына да түзә, ә кайберләре бу кыланышларны ачыктан-ачык хуплый.

Озакламый Минзәлә татарларын Арчаныкылардан аерып куярлар. Һәммәсенең үз теле, үз графикасы, үз әдәбияты, үз геройлары барлыгы ачыкланыр.

Милләтнең көче кая сарыф ителгәнен «болгарчылар» мисалында күп елларга сузылган мәгълүм фарс ачык күрсәтә. Алар «болгар» дигән мөстәкыйль халыкны рәсми рәвештә танытырга тырышып озак азапландылар. Судлар аркылы паспортларына «болгар» дип яздырырга йөрделәр, моның белән горурландылар. Ә хәзер исә Русиянең яңа паспортларында «милләт» графасы бөтенләй бетерелде. «Болгарчылар»ның тормыш мәгънәсенә тиң олы эшләре кирәксез булып чыкты. «Болгарчылар» кемнеңдер заказын үтәделәр һәм бүген аларның татардан башка беркемгә дә кирәкләре юк.

Керәшеннәрне дә, Себер татарларын да, башкортларны да шул ук язмыш көтә. Алар — бүгенге зур сәяси уенның тамгалы кәртләре генә. Һәм, асылда, татарлардан башка беркемгә дә кирәк түгелләр!

Колларга хуҗалары кухнясында бер-берсен ашарга язган.

Хикмәт Столыпинда, большевикларда һәм федераль үзәк сәясәтендә генә түгел. Озак еллар буе иң күренекле галимнәр татар теленең диалектларын эзләү белән шөгыльләнделәр, мәдәниятнең иң нечкә үзенчәлекләренә үтеп керүләре белән масайдылар. Алар мишәрләрнең, Себер һәм Әстерхан татарларының гына түгел, Пермь, Казан арты, Чистай, Сергач, Биектау, Азнакай һәм башка татарларның да бер-берсеннән аерымлыкларын таптылар. Диалектлар үрчетү белән мавыгып, халыкның бердәмлеге турында тәмам оныттылар. Галимнәрне аңлап була: диссертацияләр яклау да мөһим эш. Ләкин алар фикерен халык тыңлый лабаса. Аларга ышана. Сүзләрең һәм гамәлләрең өчен җаваплылык үлчәме булырга тиештер бит инде!

Галимнәрнең зур-зур төркемнәре «Идегәй» дастанының вариантларын тикшерделәр һәм аның казах, нугай, башкорт, татар һәм башка вариантларын бастырып чыгардылар. Авторы да бер үк, теле дә бер үк, дастаны да бер үк иде югыйсә. Төптәнрәк уйласаң, халкы да бер үк бит.

Бер галимгә мәсьәләнең асылын аңлату өчен, этием Сибгат Хәким иҗатыннан бер мисал китердем. Сугыш елларында аның сүзләренә язылган «Юксыну» дигән җыр халык җырына әверелгән. Һәм фольклорчылар аның төрле районнарда 34 вариантын тапканнар. Хәтта бер мәзәк хәл дә булган. Бервакыт эти бер мәҗлестә үзенең шушы җырын җырлаганнарын тыңлап утыра икән. Кунаклар арасында бәхәс купкан. Берәү икенчесенә, сүзләрен дөрес җырламыйсың, дип бәйләнә, ә тегесе үз вариантын яклый ди. Алар җырның өстәл янында моны елмаеп күзәтеп утыручы авторы барлыгын да онытканнар. Бәлки, «Идегәй» дастанының авторы да күкләрдән шулай күзәтеп торадыр? Әмма елмая микән ул? Галимнәребезнең көчәнүләренә карап, күңеле әрнидер аның. Бар көчне автор вариантын торгызу өчен куеп, сәясәтчеләр белдеге белән төрле халыкларга бүлгәләнгән төркиләр арасында «Идегәй»нең нәкъ менә шул бердәнбер вариантын таратасы иде дә бит…

2002 елда халык саны алу алдыннан Мәскәү демографлары татарларны бүлә башлагач, шунысы ачыкланды: безнең галимнәребез генә түгел, иҗтимагый оешмаларыбыз да халыкның бердәмлеге максатында эшләмәгән икән. Ни эш кырганнар соң алар? Татарларның бөтендөнья конгресслары шау-шулы тантана итеп уздырылды. Аннан соң башкарма комитет күпсанлы очрашулар, концертлар, җыелышлар үткәрде һәм ун ел гомер сизелмичә узып та китте. Нәрсәгә ирештек соң? Нугайбәкләр бездән аерылды, керәшен һәм Себер татарлары «без — мөстәкыйль халык» дигән дәгъва белдерде, татар-башкорт мөнәсәбәтләре тәмам буталып бетте. Өстәвенә латин графикасына күчүгә Дәүләт Думасы гына түгел, конгресснең икенче съездында шуны яклап тавыш биргән кайбер татарлар да каршы төште.

Милли-мәдәни автономияләр кәгазьдә генә яши. Алар халык тормышында ни сәяси, ни икътисади, ни мәдәни фактор була алмадылар. Әлеге оешманың мөмкинлекләр киңлегенә карамастан, эшчәнлек нәтиҗәләре түбән, һәрхәлдә, федераль дәрәҗәдә бернинди нәтиҗәсе юклыгы анык. Бүген татар сабантуй үткәрүдән гайре зур эшләргә сәләтсезмени?

Безнең эшкуарларыбыз кайда соң? Татарларның күбесе акча эшли белә һәм татар тарихы, мәдәнияте турында сүз куертырга да ярата. Кайберләренең хәтта бу хакта үз фикерләре дә бар. Шул ук вакытта мәдәни үзәкләр мохтаҗлыктан интегә һәм Татарстаннан ярдәм көтә.

Революциягә кадәр татарларның мәгариф системасы тулысы белән эшкуарлар акчасына эшли. Шушы җирлектә Казанда гына түгел, Уфа, Оренбург, Троицк, Петербург һ.б. шәһәрләрдә татарның көчле мәдәният үзәкләре барлыкка килә. Бүген исә татар эшкуары, матбугатка акча биргәнче, иске «Мерседес»ын яңага алмаштыруны кулайрак күрә. Иң яхшы татар журналы «Шура»ны һәм иң яхшы татар гәзите «Вакыт»ны үз акчасына чыгарган бертуган Рәмиевләр юк шул инде бүген. Безнең татар эшкуары, акча-фәлән җәлләмичә, бай мәҗлес үткәрә ала. Йә булмаса мәчет төзергә акча бирергә мөмкин. Бары тик ахыр чиктә генә, теләр-теләмәс кенә, берәр китап бастырырга ярдәм итәчәк. Революциягә кадәр ак һәм кара эшкуарлар булган. Аклары байлыкларын халык белән бүлешкән, каралары акчаны җилгә сибеп яшәгән. Ә бүген исә бөтен татар дөньясына мәгълүм меценатлар юк.

Имамнарыбыз, мөфтиләребез ни кылдылар? Алар күп мәчетләр төзеделәр. Һәм, мөселманнар бердәмлеген кайгыртучы рухи остазлар буласы урынга, бик яхшы прорабларга әйләнделәр. Курсавины, Мәрҗанине, Муса Бигиевне алар арасыннан бик сирәкләре генә искә ала, ә инде әлеге күренекле теологларны укып караганнары аннан да азрак. Күпсанлы мөфтиләр бер-берсе белән талашып, мәхәллә бүлешеп, зәһәрлекләрен күрсәтеп, ил күләмендә адәм мәсхәрәсенә калдылар. Оят!

Тәлгат Таҗетдин өчен Казан — гомер бишеге. Ул безнең шәһәрдә туып үскән, укыган. Ә хәзер аның өчен Казан — ваһһабичылык оясы. Ә бит Казанда бернинди ваһһабичылыкның булуы да, аның берәр каян үтеп керүе дә мөмкин түгел. Таҗетдин хәзрәт моны барысыннан да яхшырак белә. Чөнки татар халкының культура традицияләре бөтенләй башка. Безнең атаклы теологларыбыз теләсә нинди фундаменталистларга каршы торырлык нигез салып калдырганнар. Таҗетдиннең бөтен Русиягә бердәнбер мөфти булырга омтылышын аңларга буладыр, ләкин рухи лидерга хас намус-вөҗдан кайда? Вакыт узар, үтәгән заказының әһәмияте калмагач, Тәлгат Таҗетдин дә шушы Казанга кайтыр, чөнки ул татардан башка беркемгә дә кирәкми. Ә татарлар аны, Зәки Вәлиди Тоганны кичергән кебек, гафу итәрләр.

Ә безнең язучыларыбыз, шагыйрьләребез, фикер хәкимнәребез нишли? Татар халкының киләчәге өчен бар әрнүне, бар идеяләрне мин язучылар тирәлегендә сеңдереп үстем. Олы әдипләрнең бу дөньядан китүен күрәм дә эчем поша башлый. Язучылар берлеге зурайганнан-зурая. Яңадан-яңа әгъзалары барлыкка килә, тик язучының дәрәҗәсе төшә бара. Совет чорында, татар иҗтимагый фикере эзәрлекләнгән заманда, язучылар сынмады-сыгылмады. Алар татарның мәдәниятен, телен һәм традицияләрен саклап калдылар. Аларның халыкка бөек хезмәтләре әнә шул. Бүген татар язучылары халыкны ни рәвешле рухландыра соң? Узганнарны искә ала…

Татар матбугаты… Ныклап карасаң, анда укыр нәрсә юк.

Татар телевидениесе… Анда карар нәрсә юк.

Кайчандыр татарлар бөек халык булган, Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан һәм башка ханлыклар белән идарә иткән. Без бүген үз-үзебез белән дә идарә итә алмыйбыз.

Без Русиядәге, төрки һәм ислам дөньясындагы үз урыныбызны аңларга, Европага һәм дөнья культурасына мөнәсәбәтебезне билгеләргә тиеш. Милләтне шундый олуг максатлар гына берләштерә, бөек бурычларны аңлау гына вак-төяк ызгышлардан арындыра ала. Быел халык саны алу матавыгы безнең барлык кимчелекләрне яктырту өчен кирәк булган, күрәсең. Борис Ельцинның бер киңәшчесе күп еллар элек миңа: «Халык саны алуның чираттагысында сез күп татарны югалтачаксыз»,— дигән иде. Ул моны белми әйтмәгән һәм Мәскәү үз бурычларын хәзергә бик яхшы үтәп бара. Татарлар өчен әйбәт сабак. Бәлки, көч һәм фикер тупларга кирәклеген, ниһаять, ныграк аңларбыз.

Тарихтан мәгълүм: татарлар һәрвакыт социаль проектларының киң колачы белән аерылып торганнар. Татар фикере тирәнгә керергә бик яратмый, ул гомуми манзарага нигезләнә. Тасвирлы әйтсәк, татар микроскопны өнәми, күбрәк телескоп куллана. Бәлки, шуңадыр татар галимнәре арасында космик киңлекләрне тикшерүчеләр ешрак очрый: Роальд Сәгъдиев, Рәшит Сюняев, Альберт Галиев — исемнәре бар дөньяга мәгълүм галимнәр. Татарлар, бер-берсен ашаудан туктап торган арада, алдынгы фикерләр, искиткеч шәп идеяләр уйлап чыгарырга сәләтле.

Кайвакыт татарлар бар гаепне урысларга һәм Русия империясенә сылтап куярга яраталар. Акланыр өчен җайлы ысул. Әлбәттә, татарларга, хәтта урысларның үзләренә дә алдынгы халык булырга комачау итә торган империя традицияләре бар. Путин империя рухына баш калкыту мөмкинлеге биреп ялгышты. Русия демократия һәм федерализм юлына ныклап басарга да өлгермәде — каршыбызда инде үткән заманнарның шәүләләре чагыла башлады. Империяне кабат торгызуга бөтен көчне туплап каршы торырга кирәк. Татарлар, һичсүзсез, ирек, демократия һәм федерализм ягына басарга тиеш.

Исегезгә төшерегез: безнең халык кайсы заманнарда көчле күтәрелеш чорлары кичерде? Күтәрелешнең беренче дулкыны 1905 елгы революциядән соң демократик ирекләр барлыкка килгән вакытка туры килә. Ул чакта күп газеталар, журналлар чыгарылган, нәшриятлар ачылган, партияләр оешкан. Татар эшкуарларының куәтле катламы барлыкка килгән. Чираттагы көчле күтәрелеш 1917 елгы революциядән соң һәм Татарстан Республикасы төзелгәннән соң була. Бездә югары уку йортлары барлыкка килә, татар теле дәүләт теленә әйләнә диярлек, яңа театрлар ачыла, опера сәнгате, симфоник музыка туа һ.б. Өченче дулкын үзгәртеп кору чорына туры килә. Республика ун ел эчендә, билгесезлектән арынып, яңа дөньяга таба тарихи ыргылыш ясады. Татарларның һәм республиканың дәрәҗәсе нык артты.

Авторитарлык һәрвакыт безнең халыкка каршы эшләде, аны исән калу-калмау чигенә җиткерде. Татарлар өчен демократия отышлы!!! Ул безнең социаль активлыкны һәм югары мәгърифәтне тулысынча кулланырга мөмкинлек бирә.

Русия бүген кай тарафка барырга белми. Ул Көнчыгыш белән Көнбатыш, демократия белән империя арасында бәргәләнә. Русия тарих чатында туктап калды. Урысның Солженицын шикелле акыл ияләре Русия җәмгыятен, бөтенләй бутап, ялгыш юлга кертеп җибәрделәр. Ун ел элек Русиядә бар нәрсә тулысынча олигархлар карамагына тапшырылды. Ә олигархларны ил язмышы кызыксындырмый. Бүген сәяси һәм интеллектуаль элита Русиянең хәлен начар күзаллый. Ул шәхсән үзенең, ахыр чиктә Мәскәү мәнфәгатьләрен кайгырта.

Урысларны сүгәргә кирәкми. Бөек урыс культурасы авыр кризис кичерә. Ул дөньяда гына түгел, БДБ илләрендә дә, хәтта үз дәүләтендә дә йогынтысын югалтып килә, чөнки аны көнбатыш китч кысрыклый. Урыслар алдында да татарларныкы кебек үк проблема тора: ничек тә исән калырга. Тик алар үзләре әле моны ахыргача аңлап кына җиткермиләр, әле һаман да бөек үткәннең хатирәләре һәм хәзерге көннең иллюзияләре белән күңелләрен юаталар.

XX гасыр башында күренекле татар идеологлары татар халкының игътибарын Европа гыйлеменә, шул исәптән урыс культурасына юнәлдергәннәр. Тукай Пушкинга ияреп язган. Ул, Пушкиннан үрнәк алып, милли шигърият тудырган. Бүген татарлар Европадан өйрәнергә тиешләр. Барлык яңа идеяләр һәм технологияләр анда барлыкка килә. Без урысның үз кыйбласын тапканын көтеп ята алмыйбыз. Гомумбилгесезлек шартларында безгә, һич икеләнмичә, тулысынча Европага йөз тотарга кирәк. Илдәге иҗтимагый кыйммәтләрне тәгъбир итүдә җаваплылыкның бер өлешен үз җилкәбезгә алу зарур.

Тукай татарларны дөньяның иң алдынгы халыклары белән рәттән күрергә хыялланган. Алдынгылар арасында булыр өчен алар дәрәҗәсенә күтәрелергә кирәк.

Испания Каталониясенең хәле Русиядәге Татарстан хәленә бик охшаш. Төрле илләрдә яшәүче каталонлылар Җир шарына сибелгән татарларны хәтерләтә. Алар — бик борынгы тарихлы, көчле культуралы, дөньяның башка милләтләре белән бер дәрәҗәдә булырга омтылучы халык. Алар моңа испанлыларны сүгеп түгел, ә Европада актив эшчәнлек алып бару юлы белән ирешергә тырышалар. Аларның башкаласы Барселона, халыкара форумнар үткәрелә торган инициативалы шәһәр буларак, һәрвакыт игътибар үзәгендә. Менә шундый халыклардан үрнәк алырга кирәк. Көчле милләт булыр өчен алдыңа башка халыклар һәм илләр игътибар итәрлек зур бурычлар куярга кирәк.

Дөньяда милли культуралар арасында каты конкуренция бара. Бу конкуренция үз эчендәге гаугалардан хәлсезләнгән милләтләргә бернинди шанс калдырмый. Шушы гади хакыйкатькә төшенү үз халкың язмышы өчен ихлас җаваплылык хисе тудыра.

Һәрчак истә тотарга кирәк, без татарлар — бер халык. Дәрдмәнд әйткәнчә:

Татарлыктан татар һич гарь итәрме,
Кеше үз исмене инкяр итәрме.
Татарлыктан татар угълы татармын,
Татар түгел димә — башың ватармын!

Кем син, татар? Уйлан! Үз җаныңны тыңла һәм җавап бир. Син бәхетсез илнең үз тамырларыннан оялганга, болгар, керәшен, мишәр, нугайбәк, башкорт исемнәре артына качкан бәхетсез гражданымы? Әллә син үз халкыңның күтәрелүенә инанучы, бөек традицияләр варисымы?

Кем син? Татар-монгол явы турындагы мәкерле уйдырмалардан оялган маңкортмы, әллә төрки даһиның үткән чорлар белән горурланучы токымымы?

Татар, син төрки халыклар гаиләсендәге урыныңны оныткансың, шуңа күрә үзеңнең бу дөньядагы билгеләнешеңне таба алмыйсың. Син кемнеңдер традицияләре койрыгында сөйрәләсең һәм, шулардан ычкынып, үз-үзеңне дөнья казанышлары дәрәҗәсенә чыгарга мәҗбүр итә алмыйсың. Үткәнеңә карап баксаң, киләчәгеңне күрерсең.

Татар, бер генә мизгелгә туктал да, милләттәш туганыңа явыз һәм нәфрәтле карашыңнан арын. Газиз милләттәшеңә үпкә саклама. Үзара ызгышны туктат. Синең бурыч — көчле булу, димәк, халыкның бердәмлеген саклау. Алай гына да түгел, син үз тирәңә төрки һәм башка халыкларны да тупларга бурычлысың, чөнки илдә буталыш барганда, кемдер гомуми киләчәгебез өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга тиеш.

Без белемле, бай, акыллы, зирәк, бер-беребезгә һәм башка халыкларга карата түземле булырга тиеш.

Без Татарстан тирәсендә, суверенитетыбызга бернинди сәяси технолог та кул суза алмаслык итеп, нык оборона боҗрасы ясап берләшергә тиеш.

## II. Тарих

Үткәнеңә карасаң, киләчәгеңне күрерсең…

Татарлар турында, «кыргый халык» дип, мәкерле уйдырма тараттылар. Моңа хәтта кайбер татарлар да ышанды. Кайберәүләр, урыс, үзбәк, казах, башкорт булуны кулайрак күреп, үзләренә башка исем таптылар. Икенче берәүләр, үз тамырларыннан оялып, тыннарын да чыгармадылар. Урыс әдәбиятында да, Европа әдәбиятында да татар һәрвакыт явыз һәм хәйләкәр, мәкерле һәм рәхимсез. Бу образ халыкны кимсетергә нык ярдәм итте.

Чынлыкта исә үз тарихыңнан оялырлык нигез юк. Безнең тарихыбыз чынлап та бөек. Һәм бу тарих әле тәгәлләнмәгән.

Төркиләр дәүләт төзи һәм аның белән идарә итә белүләре белән дөньяга танылган. Садри Максуди безнең халыкның рухын, булдыклылыгын әнә шулай бәяләгән. Төрки каганат, Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Кырым, Себер һәм башка ханлыклар — шушы гаять зур дәүләтләрне санап кына чыгу да уйланырга мәҗбүр итә. Татарның даһилыгы гасырларга сузылган туктаусыз төзелеш, сугыш, җиңү һәм җиңелүгә сарыф ителеп беткәнме әллә? Татар үз потенциалын кайда, кайсы чорда һәм ни сәбәпле югалткан соң?

Бәлки, Алтын Урданың чиксез киңлекләрен үз иңнәренә салырга көч-куәт җитмәгәндер? Әллә ханлыкларга таркалу, татар белән татар арасына чөй кагып, кирәкмәгән көнчелек тудырганмы? Яки Казанны яулап алуда татар гаскәрләренең дә катнашуы халкыбызның рухи таркалышына китергәнме? Ничек кенә булмасын, татар XVI гасырдан бирле кабат аякка басарга тели, ләкин иң мөһим тарихи үзәген генә таба алмый аптырый. Идел-Урал Штаты оештыру бу хәлне төзәтер иде, әлбәттә, әмма ул чакларда көч җитмәгән, бердәмлек булмаган. Большевиклар, Татар-Башкорт республикасы проекты тәкъдим итеп, дилбегәне үз кулларына алганнар. Соңыннан татарлар өстеннән катгый күзәтчелек урнаштырганнар. Мәскәү бүген татар халкының бердәмлегенә юл куймаячак, аны башкортлар һәм башка халыклар белән берләштермәс өчен бар көченә тырышачак. Чөнки болай идарә итү җиңелрәк. Бу — империя традициясе. Тик заманалар алмашынып бара бит.

СССР таркалганнан соң, ил үзгәрде. Дәүләтнең биләмәсе кечерәю — сан ягыннан түгел, сыйфат ягыннан үзгәреш ул. Икътисади һәм демографик мөмкинлекләр күзгә күренеп кимеде. Илнең икътисады чыгымлырак була башлады, көньяк өлеше төшеп калу аркасында конкурентлык сәләте кимеде, ә үзара элемтә проблемалары шул килеш калды. Русия чынлыкта Каспий, Кара һәм Балтыйк диңгезләрендә үз йогынтысын югалтты. «Яңа Русия»дә Петр I казанышларының берсе дә калмады.

Моңарчы Русиядә дәүләт төзелеше мәсьәләсе беркайчан да бу кадәр кискенләшмәгән иде әле. Һәм төп сәбәп аңа каршы корылган мәкерлекләрдә түгел, ә һаман да традицион үзаң, империячелек инстинкты саклануда. Аек акыл бөекдержавачыл сафсата һәм уйдырмалар белән алыштырылды. Илнең бюджеты сизелерлек кечерәеп барган бер мәлдә сәясәтчеләр һаман хыял диңгезендә йөзәләр. Безнең илдә финнарның мобиль телефоннар сатучы «Nokia» компаниясе бюджеты Русия бюджетыннан зуррак. Шул хәлдә держава турында сүз йөртү мөмкинме?! Оптимистлык өчен нигез юк.

СССР җимерелү белән беррәттән «Бөек Русия» дә таркала башлады. Урыс шәһәрләренең анасы Киев чит илдә бүленеп калды. Бәс, шулай булгач, нишләп әле Казан Русия составында калырга тиеш ди? Дәүләт таркалуны кем һәм нинди чикләрдә туктатып калыр? Русиянең табигый чикләре кайда?

Русияне Киевтан башка күзаллап була, ләкин Казаннан башка — юк. Тарихтан мәгълүм: Русия Казан ханлыгын яулап алганнан соң барлыкка килгән. Аңа кадәр Русия түгел, Московия булган. Бүген Мәскәү белән Казан арасындагы мөнәсәбәт символик мәгънәгә ия — Мәскәүнең урыс булмаган халыклар белән уртак тел таба белүе нәкъ менә шушында күренә.

Русиянең СССР җимерелгән вакытлардан башланган таркалуын Русия тарихын яңадан барлап чыгуга нигезләнгән башкача сәясәт кенә туктата ала.

Русиянең тамырлары — православие дә, ислам да; монда славян башлангычы төрки башлангыч белән бергә үрелгән. Бу — Русиянең генетик коды, аннан качып та, котылып та булмый. Әлеге код илнең киләчәген билгеләячәк. Башкача әйткәндә, Русиянең ике таянычы, ике баганасы бар — Киев Русе һәм Алтын Урда. Русиядә милли идеянең һәм реаль сәясәтнең буталчыклыгы нәкъ менә шуның белән исәпләшмәүдән, Петр-Екатерина традицияләре йогынтысында татар мирасыннан оялып баш тартудан килеп чыга.

Гомер узар һәм Идел буендагы зур шәһәрләрнең Алтын Урда нигезенә салынганын һәркем ачык күрер. Һәм Бату хан фигурасы кешелек алдына җимерүче түгел, бөек төзүче сыйфатында килеп басар. «Татар ясагы» уртача салым (10%) дип кабул ителер, Алтын Урданың финанс системасы Урта гасырлар чорындагы иң яхшы система дип танылыр. Тарихи документларны җентекләп карасалар, урыслар үзләре дә күрерләр: православиенең чәчәк ату вакыты Алтын Урда чорына туры килә. Чөнки Чыңгыз хан законнары («Яса») буенча барлык дини оешмалар салым түләүдән азат ителгәннәр. Ә Алтын Урда «изү»еннән котылганнан соң монастырьларның матди хәле бик авырлаша һәм алар ябыла башлый. Русия дәүләтендә почта (ямчылык) хезмәтенең дә башка күп институтлар белән беррәттән татар мирасы буларак әле бик озак вакыт эшләп килгәнлеге дә ачыкланыр.

Русиядә Чыңгыз хан рухы һәрвакыт яши. Русиянең бар тарихы — Монгол империясе чикләрендә дәүләт торгызуга омтылыш.

Мәскәү — Алтын Урда тудырган шәһәр, чөнки ул «татар ясагы» җыю аркасында аякка баскан һәм абруй казанган, аннан соң, шушы өстенлектән файдаланып, үз тирәсенә урысның башка кенәзлекләрен туплаган. Дмитрий Донской татарларга каршы сугышырга уйлап та карамаган, ул лояль татарлар белән бергәләшеп, законлы хакимиятне яклап, литвалыларга таянучы узурпатор Мамайга каршы чыккан. Туктамыш хан исә Мәскәүгә Дмитрийны ясак түләргә мәҗбүр итү максаты белән яу чапкан. Заманча әйтсәк, ул Урыс олысындагы тәртипне дәүләттә урнаштырылган гомуми тәртипкә тәңгәлләштергән генә.

Бу дәвердә татарның ахыргы максаты урыс җирләренә һич бәйле булмаган. Татарлар бөек далалар аркылы Европага ыргылганнар, урманнар зонасына бик кагылмаганнар, чөнки анда атлы гаскәр бар осталыгын күрсәтә алмас иде. Сәяси көчләрнең ул чактагы бүленеше буенча урысларның татар өчен дошман булуы мөмкин түгел. Икътисад күзлегеннән караганда да, аларның татар кызыгырлык әллә ниләре булмаган.

Русияне Петр махмырыннан соң рәхимсез тарихи айну көткән.

Бүген бик күп тарихи әйберләрнең мәгънәләренә кабат төшенү бара. ЮНЕСКО Чыңгыз ханны үткән меңьеллыкның атаклы кешесе дип таныды. Гитлер шикелле явызлыгы белән түгел, ә дөньяви процессларга иң көчле йогынты ясаган бөек шәхес буларак танылды. Эрмитаж оештырган «Алтын Урда сәнгате» дигән күргәзмә зур уңыш белән дөнья буйлап сәяхәт итә. Алтын Урда белән кызыксыну елдан-ел көчәя генә барачак.

Күренекле хирург Ренат Акчурин «Русиядә «татар мәсьәләсе» дигән программ-мәкалә язган. Ул анда сүз җаеннан гына республиканы «суверенлаштыру шаукым»ында гаепләп узган, үзе татарча аңламаса да, татар теленең латин графикасына күчүе татарлар ихтыярына каршы килә дип белдергән; Бөтендөнья татар конгрессының II съездында кабул ителгән мәгълүм карар аның өчен әһәмиятле түгел икән. Ул татарның ультрамилләтчеләрен тапкан һәм хәтта Әнкара «кулы уйнавы» турында да өстәргә онытмаган. Җыеп әйткәндә, безнең республикага каршы «дәлилләр»нең гадәти җыелмасын тәкъдим иткән. Хирург Акчурин, аталарча кайгыртучанлык күрсәтеп, Идел Болгарстанын һәм Алтын Урданы үз чорының иң алдынгы илләре дип санаучы яшь татар историографиясенең «балалар авыруы» барлыгына диагноз да куйган. Аның фикеренчә, бу — «аберрация, ягъни Казанның тарихи карашны бозып күрсәтүе».

Тарихчы бервакытта да йөрәкне шунтирлауда хирургка киңәш бирергә җөрьәт итмәс иде. Нигә соң хирург, хәтта бөек булса да, тарих фәнен хирургиядән түбәнрәк яки гадирәк дип саный? Тарихта да белгечлек кирәк түгелмени? Алтын Урданы тикшергән галимнәрнең берсе дә әлеге дәүләтнең дөньяви әһәмиятен шик астына алмый бит. Моны белү өчен академик әдәбиятка күз төшерү дә җитәр иде, урыс телендәме, инглиз, венгр яки немец телендәме — бусы мөһим түгел. Чөнки Идел Болгарстаны һәм Алтын Урда турындагы әлеге фикер гомум кабул ителгән һәм биредә беркем дә бәхәс куптарып маташмый. Аберрациянең монда ни катнашы бар?

Күренекле татар сәясәтчеләре арасында иң якты йолдыз — Йосыф Акчура — төркичелек идеясе авторы (Ренат Акчурин терминологиясендә «яңа пантюркизм»). Йосыф Акчура Төркиягә качып китәргә мәҗбүр булган һәм Кемаль Ататөрек аны үзенең киңәшчесе иткән. Төркия республикасын төзүгә ул да зур өлеш кертә. Йосыф Акчура татар дәүләтенең торгызылуын күрергә хыяллана һәм безнең халыкны төрки дөньядан башка күз алдына да китерми. Моның кемгә зыяны бар? Русиягәме? Урысларгамы? Ни өчен славяннар берлеге оешмас борын яхшы да, ә төрки берлек оешмас борын начар икән? Патша чиновникларының татарга каршы алымнарын кабатлау нигә кирәк соң? Без бит цивилизацияле кешеләр!

XX гасыр башында татар фикере күренекле шәхесләрнең тулы бер йолдызлыгын тудырды: Йосыф Акчура, Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Зәки Вәлиди, Рәшит Арат — алар барысы да Төркиягә китәргә мәҗбүр булганнар, үз дәүләтләренә түгел, башка дәүләтнең чәчәк атуына хезмәт иткәннәр. Муса Бигиев язмышы да шундый, үз иленнән сөрелгәч, ул мөселман дөньясына хезмәт итә. Бу галимнәрнең һәрберсе татар фикере тарихында тирән эз калдырган. Ватанда калган Мулланур Вахитов, Солтангалиев безнең дәүләтчелекне торгызырга тырышып караганнар. Аларның язмышы да фаҗигале. Татарның киләчәге хакына, тарихны гаять тирән аңлаган, ана телен, гарәп, төрки, Европа телләрен гаять яхшы белгән нинди зур гыйлем ияләре эшләгән! Аларның фәнни хезмәтләре әле хәзергәчә искерми.

Бүген теләсә кем, хәтта үз телен һәм тарихын белмәгән кеше дә үзен Русиядә «татар мәсьәләсе» турында фикер йөртергә хаклы дип саный. Оят һәм аяныч…

Алтын Урда — данлы мирас, аның өчен Мәскәү Казан белән сугышкан. Казан ханлыгын буйсындыру Иван Грозныйга халыкара документларда үзен патша дип атарга мөмкинлек биргән. Бу исем ул чакта хан дәрәҗәсенә тәңгәл була. Бүген Русия гербында ике башлы бөркет өстендә өч таҗ көязләнеп тора — Казан, Әстерхан һәм Себер ханлыклары символлары. Алар татар ханлыкларын яулап алу хөрмәтенә Алексей Михайлович тарафыннан 1625 елда куелган. Хәер, ике башлы бөркет үз вакытында Җанибәк хан акчаларына сугылган булган. Ул заманда татар мирасыннан баш тартмаганнар. Киресенчә, Казан белән Мәскәү каршылыгына**,** этник һәм дини төсмерләрдән бигрәк, Алтын Урдадан калган киңлекләрдә сәяси йогынты өчен көндәшлек хас булган.

Русия безнең өчен чит биләмә түгел. Татарлар халык буларак шушы зур киңлекләрдә оешканнар һәм бүген дә үзләренең газиз җирләрендә килмешәкләр кебек түгел, хуҗалар булып яшиләр. Шулай булгач, без үзебезне тиешенчә тотарга, ягъни шушы җир язмышы өчен җаваплылыкны аңларга тиеш.

Тарих бервакытта да гади һәм берьяклы гына булмый, гәрчә шулай дип күрсәтергә тырышсалар да. Ә инде татар тарихы һәрвакыт катлаулы борылышларга бай. Безнең халык өчен иң авыр мәсьәлә — татар-монгол явы темасы, татарларны монголларга бәйләп күрсәтүдер, мөгаен.

Татарлар һәм монголлар, әлбәттә, төрле халык. Әмма тарих бит ул телләрне һәм этник үзенчәлекләрне аерган кебек үк җиңел бүлгәләнми. Гасырлар буе үзара көрәш һәм үзара йогынты нәтиҗәсендә бик күп нәрсә кушылып беткән. Бу хәл урта гасырлар башында ук Азия континенты үзәгендә башланып**,** Европа территориясендә тәмамланган. Ике халык бер бәйләмгә эләккән. Монголлар төркиләрдән күп нәрсә алганнар һәм үзләре дә татарларга шактый йогынты ясаганнар, аеруча хәрби сәнгать һәм дәүләт төзелеше өлкәсендә. Без монгол мирасыннан ваз кичә алмыйбыз. Ахыр чиктә, Казан Кремлендә күмелгән ханнар Чыңгыз токымыннан. Без аларны үзебезнең борынгы бабаларыбыз буларак олылаячакбыз әле.

Русия дәреслекләрендә, матбугатында, әдәбиятында, публицистикасында «татарщина», «татарская дань», «татаро-монгольское иго» дигән тезмәләрне әледән-әле кулланып торалар. Куликово кырындагы сугышны урыс тарихының хәлиткеч вакыйгасы дип күкләргә күтәреп күпертеп күрсәтәләр. Гәрчә урысның үз тарихчысы Ключевский күпсанлы әсәрләрендә әлеге вакыйганы «әһәмияте булмау сәбәпле» хәтта телгә дә алмый. Мәсәлән, Бату хан үзенә уллыкка алган Александр Невский, рәсми фараз буенча, татарга каршы иң төп көрәшче булган, имеш. Тарихи дөреслекне әнә шулай бозып бетерделәр инде.

Лев Гумилев исә татар-монгол изүе булмаган, киресенчә, татарлар һәм урыслар тевтонлылар һәм литвалылар ябырылуына каршы берләшкәннәр дип раслый. Ихтимал, ул бу вазгыятьне бераз идеаллаштыргандыр да. Татар-монголлар гуманистлар түгел, ләкин рәхимсезлек буенча ул чордагы Европадан бернәрсәсе белән дә аерылып тормаганнар. Хәтерләсәгез, ул чакта Европада тәре походларында кан түгелгән, инквизиция еретикларны учакларда яндырып үтергән. Европаны Чыңгыз ханның галәми масштабтагы ниятләре генә куркыткан, күрәсең. Шуңа җавап итеп татарлар турында мәкерле уйдырмалар чыгарганнар.

Татарларның иң беренче бурычы — җәмәгатьчелекнең безнең тарихка мөнәсәбәтен үзгәртү. Бу бурыч Татарстанның рәсми структураларына, ТР Фәннәр академиясенә генә түгел, бөтен татар халкына кагыла. Бу — гомуммилләт эше. Русиянең татарларга карашын тиз арада башка юл белән үзгәртеп булмаячак. Мәгълүмат чараларында хакыйкатьне күрсәтү өчен бернинди мөмкинлекне дә ычкындырырга ярамый, теләсә нинди форсаттан файдаланырга кирәк. Федерациянең һәрбер субъектындагы милли-мәдәни автономияләр каршында бу эш белән махсус шөгыльләнүче тарих сөючеләр төркеме оештырылырга тиеш. Бүгенге көндә иң катлаулы сорауларга җавап бирерлек академик әдәбият җитәрлек, ләкин тарих темасына популяр әдәбият бик аз. Әлеге активистлар үз төбәкләренең тарихын тикшерергә, Русия җиренең тарихи катламнарын күрсәтергә тиеш. Безнең өчен ап-ачык: Әстерхан ул — Хаҗитархан, Волгоград — татар тамырлы Сарацин, Саратов Алтын Урданың Үкәк шәһәре нигезенә салынган һ.б. Ә урысларның күпчелеге өчен бу зур яңалык булачак.

Тарих буенча популяр әдәбиятны, аеруча балалар китапларын зур тираж белән басарга кирәк. Моны Татарстанда эшләгәннәрен көтеп ятасы түгел. Белемле һәм инициативалы эшкуарлар, моны үз кулларына

алып, коммерциячел нигезгә куйсыннар иде. Бу фикерне бер үк вакытта өндәү дип тә, мөрәҗәгать дип тә итеп кабул итегез. Чөнки хәзерге вакытта Тарих институтына академик эш йөкләнгән, биредә «Татарларның борынгы чорлардан тарихы» дигән җиде томлык хезмәт әзерләнә. Киләсе 3 — 4 елда башка эшләргә бүленү мөмкинлеге юк. Институт инде моннан башка да үз мөмкинлекләреннән артыграгын башкара. Шул ук вакытта ул татар тарихын язу эшенә республика тарихчыларын гына түгел, Русия һәм халыкара фәнни үзәкләрнең дә иң яхшы галимнәрен тарта.

Казанның якынлашып килүче 1000 еллыгы уңаеннан Русиянең татарларга килмешәкләр һәм урысларны изүчеләр дигән карашын үзгәртергә бик шәп җай чыга.

Быел Иван Грозный гаскәрләренең Казанны яулап алуына 450 ел тула. Русиянең рәсми хакимияте ханлыкны буйсындыруны прогрессив күренеш дип күрсәтәсе килә. Татарлар моның белән бервакытта да килешмәячәкләр, билгеле.

Казанны буйсындыру — безнең язмыштагы фаҗигале борылыш. Әлеге дата үткән заманны түгел, киләчәкне уйларга сәбәп булырга тиеш. Аны нәфрәт кабызу өчен түгел, татар һәм урыс тарихына аек караш булдыру максатында файдаланырга кирәк.

Татар аңы тарихны ике өлешкә бүлә: Казанны алганчы һәм Казанны алгач. Моңарчы мәгълүм тарих урысларның татарга каршы, православиенең исламга каршы көрәше итеп күзалланды. Чынлыкта исә тарих катлаулырак. Тарихи вакыйгаларны Куликово сугышы мисалындагы кебек сәясәтләштерү яхшыга илтми. Бу Казанда гына түгел, бөтен Русиядә яшәгән татарлар файдасына булмаска мөмкин. Үзәкнең басымына шундый ук басым белән җавап бирергә ярамый. Зирәгрәк булырга кирәк.

Русия үзенең бөеклеген югалтты. Хәзер Русия җаны үткән чорлар даны белән бүгенге катастрофик хәле арасында бәргәләнә. Урыс культурасы да үз абруен югалта бара. Бөек Толстой, Достоевский, Чехов, Бердяев кайда бүген? Алар юк. Бу — ил өчен зур бәла. Русия православиеле урыс дәүләте булып кылана, башка халыклар белән исәпләшми диярлек. Хакимият вертикале төзергә, Татарстан һәм башка республикаларның хокукларын чикләргә, чечен мәсьәләсен көч кулланып хәл итәргә маташу үлем ачысына охшап кала.

Империяләр чоры узды. Русиянең киләчәге — бары тик демократик федерация төзүдә генә. Һәм ул федерациядә республикалар, өлкәләр, крайлар декоратив түгел, реаль субъектлар булырга тиеш. Русиянең сәяси элитасы дәүләт һәм халык белән әледән-әле экспериментлар ясап торачак, субъектларны яңа административ берәмлекләргә берләштереп, республикаларны юкка чыгарырга тырышачак. Билгесезлек һәм тотрыксызлык сәяси технологларга җәмәгатьчелек фикерен теләгәнчә болгатырга ярдәм итә.

Безнең бурыч — Русиядәге сәяси вазгыятьне тотрыклы итүгә булышу, ә моның өчен татарларның булган структураларын, иң элек милли-мәдәни автономияләрне ныгыту зарур.

Без бу тиз үзгәрүчән дөньяда үз юлларын таба белгән халыклардан үрнәк алырга тиеш. Кечкенә генә Эстонияне карагыз әнә: ул, һич икеләнмичә, шунда ук Европа традицияләренә таба юнәлде. Бу илнең икътисади яктан Татарстанныкы кебек мөмкинлекләре юк иде. Эстоннарның саны да бары тик 1 миллион гына. Ләкин алар алга киткән илләрдән өйрәнәләр һәм соңгы ун ел эчендә шактый уңыш казандылар. Иң мөһиме — эстоннарның Европа халыклары арасында үз урыннары, димәк, киләчәкләре бар.

Татар тарихы Азия континентына тирән үтеп кергән — һуннар державалары, төрки һәм татар дәүләтләре җитлеккән чорларга тоташкан. Тамырларыбыз — шунда. Яңа эра башында һәм шулай ук Идел-Урал төбәгендә бөек көчешләр чорында безнең халыкның үзәге оешкан. Соңрак, язмыш тәкъдире буенча, күп кенә этнослар: болгарлар, кыпчаклар, нугайлар, һ.б. тарихыбызга бәйле көчле процессларга тартып кертелгәннәр. Татарның йөзен, асылын Алтын Урда иҗат иткән. Тел, әдәбият, культура, психология Алтын Урда чорында ук камил чагылыш тапкан. Хәер, XX гасыр да милләтне үзгәртте, аңа заманча, Европа үзенчәлекләре бирде. Безнең халыкның тарихы — туры мәгънәдә дә, күчерелмә мәгънәдә дә— Көнчыгыштан Көнбатышка туктаусыз хәрәкәттә. Кайчандыр алдынгы фикер һәм югары культура Көнчыгышта булган. Әмма дөньяви процесслар үзәге әкренләп Көнбатышка күчә барган. Бүген Европа — иң либераль идеяләр үзәге, нәкъ менә Европада халыклар хокукларына зирәк мөнәсәбәт яшәп килә. Фән һәм техникада алдынгы фикер, алга киткән икътисад һәм мәдәният тә Европада. Русия Көнчыгыш һәм Көнбатыш арасында торырга тырышып нык ялгыша. Безнең бурыч — Көнчыгыштан аерылмыйча гына Европага таба үрләү.

Татарлар тарихта дан-шөһрәт дәвере дә, кимсетелү заманнары да кичерделәр. Телебезгә, культурабызга, динебезгә карата дүрт ярым гасырга сузылган эзәрлекләүне без лаеклы уздык, ана телебезне һәм абруебызны саклап калдык. Болар барысы да үлеп баручы империянең койрыгында сөйрәлү өчен эшләндемени соң? Юк, без цивилизацияле җәмгыятькә юнәлгән үз юлыбызны, Русиягә каршы барып та, аннан чыгып та түгел, Русия белән бергә табарга тиеш.

**Татар, син үз тарихың турында дөреслекне белергә тиеш.**

**Татарлар кыргый халык булган дисәләр дә — ышанма.**

**Татар-монгол изүе Русиянең һәм башка илләрнең үсешен тоткарлаган дисәләр дә — ышанма.**

**Без татарлар түгел, без — болгарлар дисәләр дә — ышанма.**
**Алтын Урданы кимсетеп сөйләсәләр дә — ышанма.**

Без — бөек культура варислары, дөньяга безнең потенциал кирәк. Татар телендә, әдәбиятында, әхлакый кыйммәтләрендә олы тарихи тәҗрибә тупланган һәм без— бу традицияләрнең варисы, ияләре. Безнең ата-бабалар Евразия киңлекләрен үзләштерә алганнар һәм иң кырыс шартларда яши алырлык дистәләгән дәүләт төзегәннәр. Төрки каганаты, аннан соңгы Алтын Урда булмаса, Русия бервакытта да барлыкка килә алмас иде.

Тарихта берни дә эзсез югалмый. Безнең бәлабез шунда ки, төрле чорларда тарих чылбырын өзәргә маташтылар, берничә буынны татарлар турында ялган укытып тәрбияләделәр. XXI гасырда кем булачагыбыз хәзер бары тик үзебезгә генә бәйле. Мескенлегебезне җиңеп, тарихи хакыйкатьне кайтару эшенә тотынырга кирәк, шуннан соң, иншалла, вакытның өзелгән чылбыры да ялганып китәр…

## III. Ана теле

Совет чорында Габдулла Тукай сүзләренә язылган «Туган тел» җыры татарларның гимны иде. Аны төрле җыелышларда рухланып-дәртләнеп җырлаганнарын хәтерлим. Бу җыр хакимиятнең ассимиляция сәясәтенә каршы протест рәвеше иде.

Без теләгәнебезгә ирештек — татар теле Татарстанда дәүләт теле дип игълан ителде һәм әкренләп бөтен Русия буйлап яңадан гамәлгә керә башлады.

Ләкин күңел барыбер тыныч түгел…

Хәзер татарларны яшьләрнең күпләп-күпләп урыс теленә күчүе борчый. Бу һәр җирдә, хәтта Татарстан шәһәрләрендә дә шулай. Җитди проблема. Әлбәттә, яшәр өчен, эшләр өчен һәм бигрәк тә Русиядә лаеклы урын тотар өчен урыс телен урыстан яхшырак белергә кирәк. Ләкин төп куркыныч — тел тармагының глобальләшүендә. Инглиз теле бөтен дөньяга ургылып тарала, яңадан-яңа илләрне һәм халыкларны биләп бара. Галимнәр исәпләве буенча, 100 елдан соң дөньяда өч тел өстенлек итәчәк: инглиз, испан һәм кытай телләре. Калган телләр язмышы — кухня теле булып калу.

Урыс теленә мондый кысрыклауга каршы тору җиңелрәк, чөнки ул сан ягыннан да, дәүләт ярдәме ягыннан да өстенлеккә ия. Хәер, Русия җәмгыяте үзе дә хәзергә дөньяви процессларга, глобальләштерү куркынычын тоярлык дәрәҗәдә катнаштырылмаган әле. Тик бу озакка бармас. Татарлар әлеге куркынычны кискенрәк тоялар. Чөнки телнең ассимиляцияләшү бәласенә без күптән тарыдык инде.

Шулай булгач, татар телен торгызу өчен бүген шулкадәр тырышырга кирәк микән соң? Татарстан гражданнары балаларын анык киләчәге булмаган телне өйрәнергә мәҗбүр итеп дөрес эшлибезме соң? Бәлки, шул тырышлыкны урыс һәм инглиз телләрен өйрәтүгә юнәлдерергәдер? Ул телләр белән югалмыйсың инде анысы. Бу бик катлаулы. Аңа тиз генә җавап табып булмый.

Өлкән буын өчен тел — изге нәрсә. Сибгат Хәким болай дип язган иде:

Язмышым, үзең аердың,
Юк әткәм һәм юк әнкәм,
Юк җирдә башка шатлыгым,
Әйтче, мин кемнән, йә, ким?
Әнкәмнән мәхрүм итсәң дә,
Телемнән итмә ятим.

Замана яшьләре прагматиклар**,** үзен саклап кала алмаган һәрнәрсәне тормыш мәйданыннан себереп ташлыйлар. Татар телен ни көтә соң? Без яшьләргә ни әйтергә тиеш?

Тарихи күзлектән караганда, татар телен яклап күп дәлилләр китерергә мөмкин, әмма тарих бүгенгегә аек караш булганда гына киләчәк файдасына эшли. Татарларның дөнья культурасында телнең гамәли кулланылыш зарурлыгын аклый торган үз киштәсе булырга тиеш.

Татарларның хәзерге дөньяда урынын билгеләячәк ике мәдәни фактор бар. Беренчесе — татар теленең төрки телләр төркемендәге төп тел статусы. Икенчесе — исламның иң алга киткән формасы буларак җәдидчелек үзенчәлекләре. Киң мәйданга чыгарлык башка казанышларыбыз юк. Димәк, татарның эшчәнлеге өчен ике мәйдан бар: төрки дөнья һәм ислам дөньясы. Татарның Русиядәге абруен да шушы факторлар билгели.

XX гасыр башында татарлар Европа культурасы белән төркиләр арасында арадашчы ролен үтиләр. Урта Азиядә күп кенә мәктәпләрне, газеталарны, нәшриятларны татарлар ачкан, үзләре шунда эшләгәннәр дә. Безнең эшкуарлар ул заманда Русия белән Көнчыгыш арасында да арадашчы булганнар. Әлеге функцияне совет чоры ясалма рәвештә юкка чыгарган. Хәзер безнең алда әлеге функцияне кайтару бурычы тора. Йөз елга кире кайтып, икенче кат омтылыш ясап карарга кирәк. Ләкин бу миссияне бермә-бер кабатларга яра-

мый. Заманалар да, вазгыять тә, ихтыяҗлар да үзгәрде. Төрки дөнья милли чикләр белән бүлгәләнгән булып чыкты һәм татарларга элеккеге рольдә теркәлеп калу хәзер катлаулырак.

Иң элек лингвистикага кагылышлы проблемаларны ачыкларга кирәк, алар, дөрестән дә, шактый җыелган. Менә иң ачык мисал. Башкорт белән татар бер-берсен тәрҗемәчесез аңласа да, мөстәкыйль башкорт теле күзгә бәрелеп тора. Бер тел белән икенчесе арасында чик кайда дигән сорау туа. Акыллы фәнни дәлилләрдән ераккарак китеп, тормыш чынбарлыгына күз салсак, бик гади итеп әйтеп була: тел кешеләргә аралашу өчен хезмәт итә. Ул — үзара багланыш коралы. Әгәр дә без үзара сөйләшкәндә бер-беребезне аңлыйбыз икән, димәк, телебез бер үк.

Минем кызым телевизордан башкортча спектакльне беренче мәртәбә өч яшендә карады һәм аңа барысы да аңлашылды. Әгәр дә беркайда да укымаган сабый бала башкорт сөйләмен аңлый икән, димәк, аның өчен башкорт теленең татар теленнән аермасы юк, бары тик әйтелештә генә үзенчәлекләр очрый. Фәкать шул гына. Тормыш таләбе шушы. Тылмач кирәкми икән, димәк, тел бер үк.

Бервакыт гаиләбез белән Кырымга ял итәргә барган идек. Анда минем кызым телевизордан кырым татарлары телендәге тапшыруларны аңлап, мавыгып карый иде. Мин моннан шундый нәтиҗә ясадым: хәтта балаларга да тел киртәсе юк икән, димәк, татарлар һәм Кырым татарлары теле дә, нигездә, бер үк, ә үзенчәлекләре әллә ни әһәмияткә ия түгел.

Төрки тел бик күптән барлыкка килгән. Ул бай гына түгел, үтә чыдам да булып чыккан. Садри Максуди: «1200 ел эчендә безнең тел бик аз үзгәргән»,—дип язган иде.

Дистәләгән төрки әдәби тел уйлап чыгару өчен күпме көч сарыф ителгәндер! Теге яки бу авазларның яки кайбер сүзләрнең әйтелеш үзенчәлегенә генә нигезләнеп мөстәкыйль телләр һәм диалектлар барлыгын белдерүче лингвистиканың ни хаҗәте бар? Ул кемгә хезмәт итә? Без бүген шул «фән»нең ачы җимешләрен татыйбыз түгелме?

XIX гасыр ахырында Исмәгыйль Гаспринский гомумтөрки телдә «Тәрҗеман» газетасы чыгара башлый. Ул төрки дөнья алдында торган проблемаларны яхшы аңлаган. Аннан соң безне революцион процессларга тартып керткәннәр. Татарлар революциянең ирек китерәчәгенә ышанганнар. Ә иректән дә кадерлерәк тагын ни бар? Әмма ирек, хөррият урынына төркиләрне совет тулай торагының милли бүлмәләренә таратканнар.

Сталин боерыгы буенча, дистәләгән төрки алфавит төзү эше вәхшиләрчә үткәрелә. Революциягә кадәр татар матбугатын патша Русиясенең барлык төрки халыклары укыган булса, бүген исә бу мөмкин хәл түгел. Без бер-беребезне сөйләм телендә генә аңлыйбыз. Иң аянычы — без әллә ахмаклыктан, әллә гадәт буенча шушы сәясәткә ябышып барабыз.

Соңгы елларда миңа немец телле күп кенә илләрдә булырга туры килде һәм мин шуңа игътибар иттем: австриялеләр, баварлылар, саксонлылар, швейцариялеләр мөстәкыйль телләрдә сөйләшәләр (мин ул чакта шулай дип уйлый идем). Бервакыт Мюнхенда, мэриядәге очрашуда бер баварлы минем белән сөйләшергә теләк белдерде, әмма тәрҗемәченең немец телендә генә сөйләшүен белгәч, кулын селтәп кайтып китте. Мин моңа бик гаҗәпләндем. Безнең югары квалификацияле тәрҗемәчебез бавар диалектында бер сүз дә аңламый икән. Баксаң, немецлар бер-берсенә һич аңлашылмый торган төрле диалектларда сөйләшәләр икән. Әмма ләкин бер үк әдәби телдә укыйлар һәм язалар.

Дәүләт теле немец теле булган Швейцариядә мин тел вазгыятен махсус тикшердем. Безне Швейцариянең Юстиция министрлыгында кабул иттеләр, без кантоннарда, Берн муниципалитетында булдык. Бар җирдә дә швейцар телендә сөйләштеләр. Люцернда исә парламент Татарстан делегациясен аягүрә басып каршылады. Безне озатып йөрүче швейцарияле алар сөйләгәнне немец теленә тәрҗемә итте, аннан соң безнең тәрҗемәчебез урыс теленә тәрҗемә ясап барды. Бу хәл миңа нык тәэсир итте. Без башкорт, кумык, балкар, карачай, нугай, кырым татар, казах, уйгур һәм башка телләрне тәрҗемәчесез аңласак та, мөстәкыйль телләр дип атыйбыз. Ә австриялеләр, баварлылар, швейцарлылар һәм башкалар, бер-берсен аңламасалар да, үз телләрен (ягъни без тел дип күзаллаган) диалект диләр. Һәм боларның берсе дә үз әдәби телен уйлап чыгарырга ашкынмый — анда законнардан башлап гади хатларга кадәр бар нәрсә немец телендә языла, газеталар һәм матур әдәбият та шул телдә басыла.

Швейцариядә, Фрибургтагы Федерализм институтында кайбер профессорлар әдәби немец теленнән бигрәк инглиз телендә сөйләшүне мәгъкуль күрделәр. Бу — глобализация шаукымы, күрәсең. Мин моңа аптырап калдым һәм сорау бирдем: «Хөкүмәттә һәм парламентта, телевидениедә һәм өйләрегездә кулланылучы камил сөйләм диалектыгыз булгач, ни өчен сез үз әдәби телегезне булдырмыйсыз?» «Моның өчен базар тар», — дип җавап бирделәр. Дөрес, кайбер немец диалектлары үз әдәби телен булдыру юлыннан киткәннәр (мәсәлән, голланд теле), ләкин аларга инглиз теле кысрыклавына каршы тору кыенрак булачак.

Даһи фикер һәрвакыт гади була. Димәк, төрки телләр өчен иң куркынычы — урыс теле дә, империя традицияләре дә, Русиянең хәзерге сәясәте дә түгел, ә БАЗАР галиҗәнаплары икән ләбаса!

Әлеге мисалдан берничә нәтиҗә ясарга мөмкин.

*Беренчесе.* Гомумән әйткәндә, төрки тел — бер. Шул ук вакытта чыгышлары тарихи дәлилләнгән әдәби телләр бар. Шул ук вакытта ясалма төстә барлыкка китерелгән дистәләгән тел яши. Әгәр дә аерым торучы чуваш һәм якут сөйләм диалектларын читтәрәк калдырсак, үз эченә күпсанлы шивәләр һәм сөйләшләр сыйдырган төп ике диалект бар — угыз һәм кыпчак. Мин бу мәсьәләгә лингвист күзлегеннән түгел, тормышның гади таләпләреннән чыгып карау максаты белән фәнни классификацияләрдән аңлы рәвештә читкәрәк китәм.

Чыннан да, татарларга төрек, азәрбайҗан, төрекмән телләрен бернинди әзерлексез аңлау кыен, әлбәттә. Ә менә без, кыпчак диалекты эчендәгеләр, бер-беребезне яхшы аңлыйбыз. Үзбәк сөйләм теле фарсы сүзләренә бай, бу хәл аралашуны кыенлаштыра. Әмма нигездә үзбәк, казах һәм кыргыз әдәби телләрен аңларга мөмкин.

Инде башкорт яки мишәр, Себер яки Әстерхан татарларына килгәндә, аларның сөйләм үзенчәлекләре татар шивәсенең бер сөйләше дигән төшенчәгә туры килә. Фәкать шул гына. Чагыштыру өчен: мәгълүм казакларның сөйләшен беркем дә мөстәкыйль тел дип санамый, гәрчә аларның үзаңы башкортларныкыннан көчлерәк, тарихи тамырлары тирәнрәк булса да.

Әгәр дә башкортлар үзләренчә сөйләшергә тели икән, рәхим итсеннәр. Ләкин безгә, төркиләргә, шулкадәр күп әдәби тел, шулкадәр күп алфавит нигә кирәк? Алар бит төрки дөньяны бүлгәләү өчен махсус уйлап чыгарылганнар! Ни өчен без демократия шартларында да сталинчыл «тел белеме» принципларын тотарга тиеш? Һәм ни өчен без телләрнең дөнья мәйданындагы кискен конкуренциясе каршында үз-үзебезне үз телләгебез белән тарихи тупикка кертергә тиеш? Һич аңлашылмый…

*Икенче нәтиҗә* түбәндәгедән гыйбарәт. Куәтле немец милләте, киләчәкне уйлап, немец культурасы ареалын саклап калу өчен австриялеләр һәм швейцариялеләр белән берләшә икән, димәк, немецларныкы кебек икътисади, административ, нәшрият потенциалы булмаган төркиләргә исән калу турында инде күптәннән кайгыртырга кирәк иде. Кыпчаклар белән чагыштырганда, «угыз» мәдәни төркеменең үсү өчен мөмкинлекләре зуррак, чөнки ул Төркия, Азәрбайҗан, Төрекмәнстан дәүләт потенциалына таяна. Үзбәкләргә дә хәзергә исән калу турында уйламаска була — алар бик күп һәм бер җирдә оешып яшиләр. Казахлар белән кыргызлар да вакыты җиткәнче үз дәүләтләренә таяна алалар. Ә менә Русиядәге төрки халыкларның бер-берсеннән аерылган хәлдә исән калу мөмкинлекләре юк. Базар мөнәсәбәтләре тиздән һәммәсен үз урынына утыртачак һәм республикалар глобализациягә каршы торырлык үзенчәлекләребезне административ көч кулланып кына саклап кала алмаячак.

Әлбәттә, Мәскәү төрки халыкларның берләшүенә каршы торачак, безнең бар омтылышыбызны, шул исәптән шушы мәкаләләрне дә, пантюркизм дип атаячак. Ләкин без хәзер һич кичекмәстән икенең берсен сайлап алырга тиеш: йә без Мәскәүнең төче сүзенә алданып әкренләп юкка чыгабыз, йә без исән калу юнәлешендә тарихи ыргылыш ясыйбыз. Ахыр чиктә безнең төрки халыкларны саклап калырга омтылуыбыз урысларга да, урыс теленә дә каршы килми. Киресенчә, Русиядә төркиләр славяннарны табигый рәвештә тулыландырып тора. Һәрхәлдә, төрки кушылмадан башка Русиягә Евразиядә урын юк.

*Өченче нәтиҗә.* Урысларны киләчәктә татарлар язмышы көтә, алар хәзергә моны аңламыйлар әле. Киләчәктә урыс, украин һәм белорус телләре (асылда, бер телнең төрле шивәләре) мөстәкыйль телләр буларак исән кала алмаячаклар. Аларга славян дөньясын цивилизация буларак үстерү максатында берләшергә туры киләчәк. Европаның күп кенә славян халыклары Германиянең икътисади һәм мәдәни басымы астына эләкте дә инде. Аларның дөньяга кирәкле телләр һәм культуралар буларак рольләре берничә дистә елдан соң бик көчле сынауга дучар ителәчәк. Совет культурасын ябык чикләр генә коткара иде. Хәзер андый чикләр юк. Бүген табигый конкуренция хакимлек итә.

Татар теленең киләге бармы соң? Бөек милләтләр арасында аңа урын табылырмы?

Татар телен төрки дөньяда мәдәни кыйммәтләр алмашуга ярдәм итә торган арадашчылык функциясе генә саклап калачак. Бу Көнбатыштагы либераль идеяләрнең төрки телдә чагылышы булачак.

Глобализация барча илләргә дә кагылачак. Тик шул ук вакытта гомумдөнья культурасын тулыландырып һәм туендырып торучы локаль культуралар саклaначак. Аерым этник культураларның конкурентлыкка сәләте гомумкешелек хәзинәләрен баету дәлиле булып калачак. Көнбатыштагы кече предприятиеләр, бер-берсе белән ярыша-ярыша автогигантларның төп конвейерына запас детальләр китергән кебек, милли культуралар да дөньяның идея фабрикаларына яңалыклар һәм ачышлар ташыячак.

Төрки культураның бөеклеге һәм әһәмияте, анда татар теленең урыны безнең ихтыярдан һәм булдыклылыктан тора.

Татарстан өчен икътисади фактор гаять әһәмиятле. Республикага үз тауарларын сатар өчен базар кирәк. Халыкара конкуренцияне һәм тауарларыбызның сыйфатын исәпкә алсак, Көнбатыш базарлары безнең өчен ябык икәне аңлашыла. Безнең өчен Көнчыгыш кала. Көнчыгыш әкренләп урыс телен онытачак. Ди-

мәк, бер үк вакытта төрки, урыс һәм инглиз телләрен белүче кешеләр кирәк булачак. Шул рәвешчә, әлеге функциянең дә кирәге чыгачак. Татар телен саклауга һәм үстерүгә бар өмет тә шунда. Нәкъ менә шул сәбәпле, Татарстанда татар балаларына гына түгел, урыс һәм башка халыклар балаларына татарча өйрәтүнең мәгънәсе бар. Бу безнең гражданнарга Азиядә эшләү өчен өстенлекләр бирәчәк.

Татарларга исән калу өчен бик каты көрәшергә туры киләчәк. Бу юлда иң беренче адым — латин графикасына күчү. Кириллица, гарәп алфавиты кебек үк, татар теле өчен уңайсыз. Бүген күпләр латиница белән баш катырырга кирәк микән дип борчылалар. Күпме чыгым тотарга һәм Мәскәү басымына каршы торырга кирәк булачак. Кириллицага барыбыз да күнеккән идек бит инде.

Минем этием Сибгат Хәким, телнең бар нечкәлекләрен дә белгән кеше буларак, теге яки бу графиканың өстенлекләренә тулысынча бәя бирә алырлык шәхес иде. Ул башта мәдрәсәдә гарәп алфавиты, аннан соң яңалиф өйрәнгән, гомер буе кириллицада язган. Ул татарларга иң тәңгәл графика — латин дип саный иде. Бу — икеләнергә урын калдырмый торган абруйлы фикер. Хикмәт бары тик шунда: латинның кайсы вариантын сайларга һәм аңа күпме вакыт эчендә күчәргә?

Бөтен дөньяның, һәрхәлдә, аның дөньяви процессларны билгеләүче өлешенең латинга күчүен исегезгә төшерү урынлы дип уйлыйм. Бу процесстан хәтта Япония дә читтә калмады. Хәзерге вакытта кириллицаны кулланган халыкларны алдынгы дип әйтеп булмый. Болар — Русия, Украина, Белоруссия, Болгария, Сербия, Казахстан һәм Кыргызстан. Әлеге исемлеккә әллә ни ис китми шул.

Татарлар өчен совет чоры нәтиҗәләреннән бигрәк, шул чор эчендә дөньяның бик нык алга китүе куркыныч тудыра. Русия юл читендә утырып калган булып чыкты.

Латин графикасы татар сөйләменең үзенчәлекләрен тәңгәл чагылдырып кына калмыйча, мәгълүмат системаларында үз урыныбызны табарга да мөмкинлек бирәчәк. Яңа гасырның асылы — мәгълүмати революция. XX гасырның символы Форд уйлап тапкан конвейер булса, яңа гасыр символы — Интернетка тоташтырылган компьютер.

Мәгълүмат системалары — тормышка йогынтысы буенча басма китап барлыкка килүгә тиң революцион күренеш. Интернетка бары тик өстәмә техник җайланма дип кенә карарга ярамый. Ул безгә өр-яңа дөнья ачты, анда чикләр дә, цензура да юк. Интернет теләсә кемгә ачык һәм санаулы минутлар эчендә, бернинди ераклыкларга карамастан, теләсә кем белән тоташтыра ала. Ул фән, икътисад үсеше, мәгълүмат алмашу өчен моңарчы күрелмәгән киң мөмкинлекләр ачты, кешеләрнең яшәү рәвешен үзгәртте.

Заман мәгълүмат системаларында үз урынын тапмаган халык тарихтан төшеп калачак. XX гасыр башында татарларның роле Русиядәге төрки халыклар арасыннан беренчеләрдән булып нәшриятлар ачу, китап, газета таратудан гыйбарәт булган. Алар Көнчыгышка яңа гыйлем китергәннәр. Бүген исә татарларның функциясе — мәгълүмат системалары төзү.

Татарларның латин графикасына күчү юлында ике киртә тора: беренчесе — сәяси — Русия хакимияте структураларының каршылыгы. Икенчесе — инде кабул ителгән алфавитның кимчелекләре.

Мәскәүнең татар латин графикасына кискен каршылыгын юридик яктан шәрехләү мөмкин. Русия Конституциясе һәм халыкара хокук үз теленең үсеш юлларын мөстәкыйль рәвештә билгеләүче халык ягында. Дәүләт Думасы исә латин алфавитына күчү илнең куркынычсызлыгына яный дип белдерде. Бу кыргыйлыкның ачык мисалы. Патша Русиясендә латин гына түгел, гарәп алфавиты да, грузиннарның һәм әрмәннәрнең үз алфавитлары да гасырлар буе гамәлдә булган. Һәм алар Русия өчен бернинди дә куркыныч тудырмаганнар. Федераль үзәк латинга каршы күтәрелеп империячел инстинктын һәм урыс культурасының үз абруен югалтудан куркуын күрсәтте. Татарларга латинга күчүне тыю Русия проблемаларын хәл итү дип уйлау көлке. Шунысы аяныч: шушы пычрак сәяси интригага бер төркем татарлар да катнашкан булып чыкты. Әмма сәясәт — вакытлы нәрсә.

Татарның латин графикасы — эшләнү чорында ук, яңалифкә кайтырга теләүчеләрнең «универсаль» алфавит яклылар белән үзара килешенүе иде. Нәтиҗәдә төрки телләргә хас, әмма татар теле өчен бик үк уңайлы булмаган хәрефләр барлыкка килде. Хәер, татар алфавитын камилләштерү мөмкинлеге бар әле: «койрыклы» хәрефләрне инглиз аналогларына алыштырырга кирәк. Мәсәлән, **s,** – sh, **c,** – ch, **n,** – ng. Бу очракта ул Интернетка җайлаша төшә, компьютер клавиатурасы гадиләшә, димәк, алфавит үзе дә универсаль һәм конкуренциягә сәләтле була. Безнең алфавит төрекләрнекеннән бер адым алгарак атларга тиеш. Төрекләр латинга күчкәндә, компьютер челтәре булмаган бит әле. Безнең төрекләрне борылышта узып китү мөмкинлегебез бар. Бу — латинга күчүнең тоткарлануын аклаучы бердәнбер нигезле дәлил.

Татарны төреккә иярүдә гаепләүчеләр әлегә аңлап җиткермиләр: төрки дөньясында угыз һәм кыпчак диалектлары арасында табигый конкуренция туачак. Һәм биредә төп рольне бер яктан төрекләр, икенче яктан татарлар дәгъвалаячак. Моның да аңлатмасы бар. Әлеге ике халыкның һәрберсе — олы тарих һәм бай культура иясе. Төрекләрнең тамыры — Госман империясе, татарларныкы — Алтын Урда. Төркиянең өстенлеге мәгълүм: халкы күп, Европа һәм НАТО белән бәйле дәүләте көчле һәм бай. Үзбәкләр, Урта Азия

традицияләренә таянып, үз юнәлешләрен анykларга тырышалар. Ләкин, казахлар шикелле үк, алар үз мәгълүмати тәкъдимнәре белән катнашырга әзер түгелләр. Моны татарлар эшли ала. Ләкин безнең дә артык мактанырлыгыбыз юк. Татарстан Республикасын Төркия белән чагыштырып булмый. Русия татарлардан курка, шуңа күрә безгә ярдәм итми. Татарлар аз, өстәвенә кесә ягы да сай. Татарларның бердәнбер өстенлеге — университетлары булу. Аларда мәгълүмат системаларын камилләштерү мөмкинлеге бар. Моннан тыш тагын шунысы мөһим: татарлар төрки халыклар арасында яши, аларның традицияләрен, мәдәни үзенчәлекләрен яхшы белә. Әгәр дә без бүген татарча латин графикасын инглиз теленә якын вариантта эшләсәк, ул Интернет өчен уңайлырак һәм үзенә зуррак игътибар җәлеп итәчәк. Һәм безнең тагын бер өстенлегебез артачак. Хәзерге вакытта яшь буын үзен Интернеттан башка күз алдына да китерми. Моны да истә тотарга кирәк.

Безгә хәзер фикер сөрешендә, телдә һәм культурада революция ясау зарур. Һәм ул татар алфавитының латинга күчүеннән башланачак. Бу — котылгысыз. Әгәр дә латин алфавиты татарларны берләштермәсә, Мәскәү безгә каршы күтәрелмәс һәм кириллицаны ныгыту максатында махсус законнар чыгармас иде. Әлбәттә, Татарстаннан читтә, аеруча Башкортстанда татар телен латин графикасында укытуга юл куелмаячак. Моннан куркырга кирәкми, моңа әзер булырга кирәк. Барча татарны да тиз арада һәм бер үк вакытта латинга күчерүгә исәп тоту кыен. Шуңа күрә күпмедер вакыт татар дөньясы, серблар шикелле, ике алфавит кулланачак.

Латин графикасына, бернинди закон да, рөхсәт тә көтеп ятмыйча, үзебезгә күчә башларга кирәк. Аны өйдә, якшәмбе мәктәпләрендә, махсус курсларда өйрәнүне, Интернетта компьютер программалары таратуны беркем дә тыя алмый. Интернетта **s,, c,, n,** хәрефләрен баштан ук инглиз хәрефләренә алыштырырга, **ә** хәрефен **a’** дип язарга кирәк. Барысы да үз кулыбызда лабаса.

Ләкин бу гына җитми. Татар Интернеты кирәк. Татар милли-мәдәни автономияләренең федераль советы Бердәм татар мәгълүмат базасы булдыру максатында күренекле галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре һәм эшкуарлардан торган махсус орган оештырырга тиеш. Бай татарлар бу программага җәлләмичә генә акча бирергә тиеш, чөнки бу гамәл отышлы: алар үзләре татар дөньясыннан иң хәбәрдар кешеләргә әйләнәчәкләр. Безнең атаклы эшкуарлар революциягә кадәр татар мәгърифәтен үз кулларына алганнар иде. Бүген мондый гамәл балаларыбызга компьютер белеме бирү, татар сайтлары ачу һәм аларны гомуми челтәргә берләштерү өлкәсендә көтелә. Татар дөньясындагы мәгълүмати революциянең стратегиясен эшләү зарур.

Язмыш татарларны дөнья буйлап тараткан. Бүгенге көндә барча татар өчен нәтиҗәле эшли алырдай оешмалар төзү авыр. Әмма глобализация аркасында бездә Интернет барлыкка килде. «Татар электрон пәрәвезе» халыкны берләштерергә, аны хәрәкәтчәнрәк итәргә булышачак. Татарларның компьютер аша аралашуына бернинди административ чикләр дә, үзәк һәм җирле хакимият каршылыгы да комачау итә алмаячак. Шуңа күрә һәрбер татар гаиләсендә кириллица һәм латинда эшләнгән татарча программалы компьютер торырга һәм ул Интернетка тоташтырылган булырга тиеш.

Татарлар борын-борыннан балаларын башта атта йөрергә өйрәткәннәр. Бүген исә аларны иң элек компьютерга өйрәтергә кирәк. Шул очракта гына алар бу дөньяда үз юлларын табарлар.

Озак уйланып һәм үзара талашып торырга вакыт юк. Бар ихтыярны бер йодрыкка җыеп, кайчандыр бабаларыбыз җәдидчелек юлына баскан шикелле, тарихи ыргылыш ясарга кирәк.

Татар, синең телеңнең киләчәге нинди? Бу хакта уйланасыңмы? Синең телеңнең меңьеллык тарихы бар. Дөньякүләм бөек дәүләтләрнең берсе булган Алтын Урдада шушы телдә сөйләшкәннәр. Ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләре, безнең дөньяга карашыбыз шушы телдә тупланган. Аның киләчәге хәзер синең кулда.

Татар, син үз тарихыңның төрки дөньядан аерылгысыз икәнен онытмаска тиеш. Димәк, киләчәкне дә шул дөньядан башка күзаллау мөмкин түгел. Катып калган ялган фикерләр белән башыңны катырма, синең кебек үк мескен хәлдә калган кардәшеңнең сүзенә колак сал. Аңа кулыңны бир — сталинчыл «тел киртәсе» калдыкларын җимереп ташла. Германиядә моны эшли алдылар бит.

Кайчандыр, татарга тылмач кирәкми, дигәннәр. Бүген алай түгел. Әмма заманалар үзгәрә һәм халкыбызның асыл сыйфатларына кире кайтыр чак җитте. Һәрбер татар урыс теленнән тыш инглиз яки башка Европа телен белергә тиеш. Ләкин иң элек син үз телеңне белергә бурычлы. Әгәр дә син ана телеңне дә, милли культураңны да белмисең икән, синең бу дөньяда беркемгә дә кирәгең юк.

## IV. Культура

Милләт яшәешенең нигезе һәм төп мәгънәсе — культура. Анда халыкның бар тарихы һәм генетик коды. Безне борынгы һәм урта гасыр татарлары белән дә культура бәйләп тора.

Культура халыкның бөтенлеген билгели һәм аны үткәннән киләчәккә алып бара.

Кеше мөселман яки христиан, йә бөтенләй атеист булырга, телен югалтырга мөмкин, әмма үз культурасы нәрсәсе беләндер кадерле икән, ул татар булып кала. Хәтерендә бары тик бер генә татар көе генә калган суръәттә дә, ул татар булып кала, чөнки бу көй аның геннарында яңгырый. «Кара урман»ның иң беренче авазларын ишетү белән татар кешесенең күңелендә татарлыгы барыбер баш калкыта.

Кара урман чыгу — хәвефле юл, аның көтелмәгән борылышлары күп. Моң — язмыш ул. Татар җаны моңнан ярала һәм татар җан биргәндә дә тальян тавышын юксына.

Польша-Литва татарлары, Идегәй кенәзгә ияреп, 600 ел элек көнбатышка киткәннәр, Польша корольләренә, Литва кенәзләренә хезмәт иткәннәр. Хәзер алар полякча сөйләшәләр, ләкин үзләренең кем икәннәрен онытмаганнар, чөнки гореф-гадәтләр саклаганнар.

Культура ул — борынгы риваятьләрне, акыл-зирәклекне, рухи хәзинәләрне туплаган әдәбият.

Культура ул — музыка, сәнгать, театр.

Культура ул — халыкның рухын, ярышка ашкынуын, егәрен саклаган сабан туе.

Бу юнәлешләрнең һәрберсе зур һәм җитди әңгәмәгә лаек. Әмма идеяләр кайдан башлана соң? Культура үсеше юлларын кем билгели? Бүгенге көндә әлеге сорауларга җавап бирү мөһимрәк дип уйлыйм.

Безнең тарихыбызда ислам дине аеруча зур роль уйнаган. Әлбәттә, дин ул үзе культураның бер элементы, ә кайвакыт иң мөһиме дә.

922 ел — бөек борылыш дәвере. Багдад илчеләренең Болгарга килүе исламны рәсми рәвештә кабул итү факты гына түгел. Бу вакыйга — аны яшь дәүләт һәм Хәзәр каганатыннан бәйсез булуын бөтендөнья тарафыннан тану да. Бу — азатлыкка бер адым була. Татарның борынгы бабалары ул заманда иң алдынгы ислам дөньясына үзләре теләп кушылалар.

Алдагы дәвер — Үзбәк ханның 1312 елгы ислам революциясе. Ул вакытта кан коела. Һәм моны көчле хаким генә булдыра ала, чөнки аңа Чыңгыз хан үзе чыгарган, барлык диннәрнең дә тигезлеген таныган «Яса»га каршы чыгарга кирәк була. Үзбәк хан заманы — Алтын Урданың чәчәк ату чоры. Без аның тарихи ролен ахырынача аңлый алмадык әле. Безгә генә түгел, Тимур белән мавыгып, бүгенге көндә үз тарихларын Алтын Урдадан башка төзеп ятучы үзбәкләргә дә әлеге шәхесне яңадан ачу зарур. Нәтиҗәдә татарлар һәм үзбәкләр бер тамырдан булып чыгачак.

Өченче бөек дәвер — исламны яңарту чоры. Җәдидләр аны XIX гасыр ахырында башлаган. Ул елларда татар җәмгыятенең дөньяви уку йортлары ачу, сәяси партияләр оештыру хокуклары булмаган. Татарлар милек мәсьәләләрендә дә, икътисади эшчәнлектә дә хокукый яктан чикләнгән. Татар үз мәдәниятен мәдрәсә эчендә генә үстерергә мәҗбүр булган. Мәдрәсәләрдә милләтнең иң алдынгы фикер ияләре җыелган.

Җәдидчеләр интеллектуаль каһарманлык кылганнар. Алар патша Русиясенең рәхимсез сәяси һәм дини басымы астында караңгы урта гасырлардан Европага ыргылыш ясый алганнар. Җәдидчелек — мәгариф системасындагы реформалар һәм исламны яңарту гына түгел, культураның да сыйфат ягыннан үзгәреше. XIX гасырда татарның бөтен фикере, әдәбияты, сәясәте җәдидчеләрнең яңартылган рухы нигезендә барлыкка килгән.

Мөхәммәд пәйгамбәр: «Аллаһы Тәгалә, һәрбер гасыр башланганда, үз өммәтенә динне яңартыр өчен кеше җибәрәчәк», — дигән. XIX—XX гасырлар ялганышында җәдидчеләр шушы миссияне үтәгәннәр дә инде.

Динне һәм мәдәниятне камилләштерү — милләтнең һәм дәүләтнең сакланып калу мәсьәләсе ул. Хәзерге вазгыять шундый ки, хәтта бик теләсәң дә, бөтен дөнья тенденцияләреннән читтә кала алмыйсың. Димәк, үз мәдәниятеңне глобальләшү процессына җайлаштыру ысулын табарга кирәк.

Җәдидчелек исламның нинди дер яңа рәвешен тудырмаган. Ул исламны, гасырлар буе өстәлә килеп, бәхәссез авторитет (тәкълид) дәрәҗәсенә ирешкән тарихи, этник чит катламнардан арындырган. Җәдидчелек европача реформа түгел, ул — исламның үзенә ят нәрсәләрдән чистарынуы.

Бүген, Төркиядәге яки Согуд Гарәбстанындагы кебек, Казан урамнарында аяк битен капларлык озын күлмәкләр кигән, яулыкларга төренгән хатын-кызларны, хәтта яшь кызларны да күрергә мөмкин. Алар шулай киенеп чын мөслимәләр булабыз дип уйлыйлар, күрәсең. Мондый киемнең исламга катышы юк, турысын әйткәндә, ул хатын-кызга бернинди ямь өстәми. Татар хатын-кызлары һәрвакыт нәфис һәм купшы киенгән. Нигә үз гүзәллегеңне югалтып, гарәп һәм төрек хатын-кызлары кебек бертөслелеккә омтылырга? Бу бит аларны җәннәт тарафларына бер генә адымга да якынайтмый. Нинди беркатлылык! Бу бит очучы формасы киеп кенә оча беләм дип уйлауга тиң.

Җәдидчелек, диннең асылына, Коръәннең үзенә мөрәҗәгать итеп, төрле «схоластик» авторитетларга тәнкыйди анализ ясап, исламга үтеп кергән уйдырмаларга һәм чит формаларга каршы чыга.

Җәдидчелек исламның татарга гына хас рәвеше түгел, ул — исламның нигези асылы, шуңа күрә дә ул универсаль.

Иң тәүге мөселман лидерлары гакылны Ходайның бөек бүләге итеп олылаганнар. Аларга тәнкыйди фикер хас булган. Иҗтиһад — бөек категория, ул яшь исламны күңелгә ятышлы һәм кызыклы иткән, шул сәбәпле ислам дөнья буйлап ташкын сыман таралган. Иҗтиһадтан баш тартучылар заманадан артка калган, мөселман илләренең күпчелеге әле хәзер дә шул халәттә яши.

Җәдидчеләр исламга кайчандыр хас булган гакыл иреген кире кайтарганнар. Кеше белән Аллаһы Тәгалә арасына беркем дә: җәмгыять тә, имам да, мөфти дә керә алмый. Кеше үз гамәлләре өчен үзе җавап тота һәм нәрсәнең хак, нәрсәнең гөнаһ икәненә үзе төшенергә тиеш. Ә моның өчен аның, әлбәттә, гыйлемле булуы шарт.

Бу үзенчәлек исламны Европага якынайта, чөнки хәзерге заман Көнбатыш культурасы тәнкыйди фикер йөртүне игълан итүдән башланган, аннан соң ул либераль идеяләрдә чагылыш тапкан.

Чын мөселман Коръән сүрәләрен ятлап, күңеленә бикләп куюу белән генә чикләнмәскә, чынлап торып гыйлем иясе булырга тиеш. Коръәнне ятлау —файдасыз гамәл, Коръәнне аңларга кирәк. Мөхәммәд пәйгамбәр: «Гыйлем юлына баскан кешегә Аллаһы Тәгалә оҗмахка юл ачар»,— дигән. Мәдрәсә гыйлем алуның ахыргы ноктасы түгел, ә беренче баскычы гына. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң дөнья турында күпьяклы һәм тирән белем бирүче университет белеме алу мәҗбүри.

Җәдидчелеккә прагматиклык та хас.

Ислам тормышка тамаша кылу өчен түгел, яшәешнең мөһим ихтыяҗларын хәл итү, чынбарлыкта туып торучы сорауларга җавап бирү өчен кирәк. Ә моңа фән һәм мәгариф ярдәме зарур. Чын имам һич югы университет белеменә ия булырга тиеш. Шул очракта гына ул башкаларны нәрсәгәдер өйрәтә алачак.

Русия ислам университетына җәдидчелек тәҗрибәсен аңлау һәм аны тарату җаваплылыгы йөкләнә. Җәдидчеләрнең фәнни хезмәтләрен барча кешеләргә дә ачык һәм аңлаешлы итәргә кирәк. Алай гына да түгел, аларның идеяләренә XXI гасыр күзлегеннән карарга кирәк.

Бүген күп нәрсә үзгәрде. Йөз ел элегрәк булганнар белән чагыштырсак, хәзер дөнья бөтенләй башка мәнфәгатьләрдә яши. Җәмгыятьтәге йогынтысын сакларга теләгән ислам замана каршылыкларына җавап бирә белергә һәм күп кенә көнчыгыш илләре ябышып ята торган иске традицияләрдән ваз кичәргә тиеш.

Хатын-кызга икенче сорт затка караган кебек мөнәсәбәт исламга иудаизмнан һәм христианлыктан кергән. Европа әкренләп моннан читләште, ә мөселман илләре һаман шул гадәтне ташлый алмыйлар.

Хатын-кызны гөнаһ чыганагы дип карарга ярамый. Коръән буенча, шайтан Адәмне дә, Хаваны да берьюлы юлдан яздырган. Коръәннең 20 нче сүрәсендә болай диелгән: «Адәм Раббысына гөнаһлы булды, дошманының ялган сүзенә ияреп максатына ирешүдән коры калды». Дин тәгълиматчыларының иң абруйлыларыннан берсе булган Муса Бигиев: «Хатын-кызның хокуклары никадәр камил һәм аларның дәрәҗәсе никадәр югары булса, иҗтимагый система да шулкадәр көчле булачак»,— дип язган. Шәрехләүчеләр Коръәннең хатын-кызлар турындагы аятьләре мәгънәсен бозып күрсәтәләр дип раслаган Муса Бигиев. Хатын-кызның Адәм кабыргасыннан ясалуы турында риваять — ул бары тик метафора, хатын-кыз табигатенең нәзакәтлелеген, нәфислеген күздә тотучы образ гына. Димәк, кабырга сөяге кебек үк нәзберек хатын-кызга карата тупас көч кулланырга ярамый.

Җәдидчелек — заманча һәм толерант юнәлеш.

Муса Бигиев Ходай Тәгаләнең абсолют мәрхәмәте тәгълиматын эшли. Аның буенча Ходайның мәрхәмәте фани дөньяда нинди дин тотуларына карамастан, үзе дөньяга яраткан һәр затка кагыла. 2 нче сүрәдә язылган: «Гамәлсез генә ышанучылардан, вә яһүдләрдән, вә нәсаралардан һәм төрле нәрсәләргә табынучылардан берәү Аллаһыга иман китереп Коръән, сөннәт дәлилләре белән изге гамәлләр кылса, андый мөэминнәрнең кылган әҗере Раббылары хозурында, аларга курку һәм кайгы булмас».

Ислам, асылы буенча татулыкка өндәүче дин, бу безнең республикада мөселманнар һәм православиеләр арасындагы дустанә мөнәсәбәтләр белән дә дәлилләнә. Кол Шәриф мәчетенең өске катында «Ислам татулыгы музее» ачарга кирәк. Моның символик мәгънәсе бар. Бу очракта мәчет Казанны саклаучылар рухын гына түгел, динебезнең толерантлыгын да чагылдырачак. Карарга килүчеләр өчен ул архитектура үрнәге сыйфатында гына түгел, нәкъ менә шуның белән дә кызыклы булачак. Кол Шәриф мәчете XXI гасыр кыйммәтләрен туплаучы уникаль музейга әвереләчәк. Тынычлык яклы ислам Татарстанның визит карточкасы булачак.

Татарларның тарихи миссиясе — ислам дөньясы һәм Көнбатыш арасына күпер салу. Дөнья христианнарга, яһүдләргә һәм мөселманнарга таркалгач, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр гүя чатнап ватылды. Шушы чатнау эзләренең упкынга әверелү куркынычы бар. Бу чатнау кешеләр җаны аша узды, аларны хәвефкә салды, күңелләрдә курку тудырды. Бүлгәләнгән дөньяны бары тик яңа кыйммәтләр генә берләштерә алачак. Алар чиста либераль гына да һәм шул ук вакытта традицион ислам кыйммәтләре генә дә була алмыйлар.

Татарстан ислам цивилизациясендә билгеле бер урын алып тора. Ул — исламның иң төньяк терәге. Татарстан географик мәгънәдә генә түгел, культурасы белән дә Көнчыгыш һәм Көнбатыш чигендә урнашкан. Без — ислам кыйммәтләрен либераль кыйммәтләр белән тоташтырган культура ияләре. Безнең өстенлегебез дә шунда.

Ислам дәүләтләренең күпчелеге алга киткән илләргә чимал чыганагы сыйфатында көн күрә. Ә Татарстан югары технологияле продукция җитештерә, фән мәктәпләре үстерә, мәгариф системалары булдыра. Без ясаган вертолетларның, самолетларның сыйфаты көнбатышныкылардан калышмаска, шуның өчен Европа дәрәҗәсендәге яшәү шартлары тудыру зарур. Юкса оттырачакбыз һәм безгә бары тик бер генә юл калачак — гарәпләр кебек, нефть сатып көн итү. Ә бездәге нефть запасы нибары 30 елга гына җитәчәк. Исламны без, һичшиксез, европалаштырырга тиеш. Бу евроислам булачак. Безне моңа тормыш үзе мәҗбүр итәчәк.

Безнең өчен Көнчыгыш — тауарларыбызны сату базары гына.

Төркиядә Татарстан ярдәме белән 1,5 метрлы телескоп барлыкка килгәч, әлеге үзенчәлекле вакыйгага игътибар итүче аз булды. Төркия бу телескоп белән чиксез горурлана, чөнки дөньяда мондый телескоп кую мөмкинлегенә ия илләр сирәк. Кайчандыр урта гасырларда Галәмне тикшерү белән Көнчыгышта шөгыльләнгәннәр. Сәмәркандтагы Олугбәк обсерваториясе иң яхшылардан берсе булган. Бүгенге көндә мөселман илләре бу юнәлештә эшләмиләр. Татарстан әлегә бу өлкәдә алгы сафта.

Исламны яңарту — татарларның дөнья культурасына яңа заманда керткән иң зур өлеше. Әлбәттә, урта гасырларда Евразия картасын үзгәрткән Алтын Урда чоры булган. Ләкин бу инде үткән заман. Хәзерге заманда без кешелек дөньясына исламны яңартуга әзер булуыбыз белән генә кызыклы. Без Тукайга яки Сәйдәшкә сокланабыз. Алар бөек шәхесләр, тик татар халкы өчен генә. Безне киң аренага алып чыгарлык нәрсә ул — җәдидчелек.

Җәдидчелек тудырган традицияләрнең берсе— татар культурасының ачыклыгы. Бу зур өстенлек һәм шул ук вакытта җитди куркыныч та. Глобальләшү уңай нәтиҗәләргә генә китерми, ул теләсә нинди милли культураны сытып үтәргә мөмкин.

Татарлар дөнья модасына сизгер. Татар дискотекалары, заманча рәсем сәнгате, җитди авангард музыка барлыкка килде. Сүз уңаеннан, бу авангардта Көнбатышның коры рациональлегеннән аермалы буларак, хиссияткә, рухи башлангычка басым ясала.

Татар культурасы гасырлар чигендә югалып калмады. Әмма аның икеяклылыгы куркыта. Бер яктан, татар чыгышлы Софья Гобәйдуллина, Рудольф Нуриев, Ирек Мөхәммәдов дөнья йолдызлары булуга ирештеләр, ләкин татар тирәлегендә түгел. Икенче яктан, оятсыз шлягерлар агымы ургыла. Көй дә, текст та, оркестровка да юк. Дискотекалар өчен арзан синтезаторларда ике-өч аккордтан һәм ике-өч сүздән торган арзан продукт җитештерелә. Тавыш юклыгы замана техникасы ярдәмендә яшерелә. Илһам Шакиров кирәк тә түгел. Рөстәм Яхин ни эшкә? Музыкаль белемең, хәтта музыкаль сәләтең булмаган килеш тә җыр язып була. Бу — үзебез тудырган вазгыять.

Совет чорында татар культурасында урыслаштыруга каршы протест элементы бар иде. Моннан үзеңнең иҗтимагый әһәмиятлелегең аңлашыла иде. Әлеге төсмер халык традицияләрен саклый иде. Ни гаҗәп: бүгенге демократия күпләрне таяну ноктасыннан мәхрүм итте. Тормышта үз сәләтләреңә тәңгәл үз урыныңны табу һәм фикерләр хакиме булу кыенлашты, ә базар исә күпләрне шабашникларга әйләндерде.

Бүген культура үсешенең юлларын кем билгеләргә тиеш? Булдыксызлар һөҗүмен кем туктатыр?

Культура үсешенең җирлеге — урта белем системасы. Татарстанда бу система төссез һәм кызыксызга әверелә бара. Үзгәртеп кору башланганда барлыкка килгән эксперименталь мәктәпләр җан тәслим кылды. Үтерелгән инициатива — тәкъдир инде ул. Татарның дөньяви мәктәпләре тыелып, татарның бар яшәеше мәдрәсәләргә ябылган кырыс патша заманнарында да безнең мөдәррисләр уку йортларының менә дигән үрнәкләрен тәкъдим итә алганнар. Бүген исә безнең мәгариф системасы Русия системасының артык бер сукыр эчәге сыйфатында кабул ителә. Бүгенге системаның унитар совет системасыннан принципиаль аермасы нидә соң? Аерма юк. Татар мәктәпләренең саны гына артты. Ләкин Татарстан бит әле татар теле һәм культурасы тирәлеге генә түгел, төрле культура һәм конфессияләр яшәгән төбәк. Бу исә мәгарифнең башка стандартларын таләп итә.

Көнбатышча һәм көнчыгышча фикер йөртү арасында бер үзенчәлек яши. Алга киткән илләрдә сәяси элита һәм җитәкче эшелон, акча салуның иң яхшы ысулы буларак, мәгариф системасын үстерүне өстен күрә. Ярлы илләрдә төп юнәлеш — чимал сату. Калифорниядә, мәсәлән, штат бюджетының 40 проценттан артыгы мәгарифкә китә. «Силикон үзәне»нең могҗизасы менә шушыннан башлана да инде. Социологик мәгълүматларга караганда, Татарстанда җитәкчеләрнең карашы нефтькә төбәлгән, ә мәгариф системасы кыйммәтләр шкаласында иң түбәндә дисәк тә ялгышмабыз. Татарстан җәмгыяте аңы өчен «нефтемания» — гадәти хәл. Мәгариф мәсьәләләрендә җәдидчеләр көнбатышча фикер йөрткәннәр, ә без көнчыгышка та-

ба, еракка тәгәрәгәнбез. Республиканың киләчәгенә нигез нефть скважинасына таянмый, мәктәпнең беренче сыйныфында салына лабаса.

Мәгариф системасының бүгенге торышын акча юклыкка яки үзәк басымына сылтау бик җиңел. Әмма мәсьәлә башкачарак тора. Йә без цивилизацияле дәүләт юлын сайлыйбыз да мәгариф системасын үзгәртүдән башлыйбыз, яки акыл белән эш йөртүче илләрнең чимал кушымтасына әвереләбез.

Бездәге фикер каршылыклары кайвакыт тетрәндереп куя. Бер яктан, Казан зур интеллектуаль көчкә ия. Биредә дистәләгән иң яхшы кафедралар, университетлар эшли, ә икенче яктан, икътисади, техник, технологик үсештә нинди дә булса өстенлекле юнәлешләр төгәл билгеләнмәгән. Татарстан Фәннәр академиясе оештырылган вакытта аңа яхшы гына интеллектуаль көч тупланган иде. Үзгәртеп кору һәм аннан соңгы елларда күп очракта Фәннәр академиясе һәм Казан университеты галимнәре ярдәмендә, татар мәнфәгатьләре, конкрет фикер рәвешенә кереп, халыкка җиткерелде. Әмма әзергә бәзер яшәү чоры узды инде. Иске ресурслар тәмам. Татарстан Фәннәр академиясе сыйфат ягыннан сикереш ясарга тиеш. Фән үсешенең башка концепциясе кирәк, ул республиканың икътисади һәм иҗтимагый үсешенең өстенлекле юнәлешләренә турыдан-туры тоташырга тиеш. Фәннәр академиясенең төп асылы да менә шунда. Фәнне университетларда да, тармак институтларында да үстерергә мөмкин. Академия фәнни тикшеренүләрне гамәлгә кертүнең икътисади һәм социаль механизмнарын тәкъдим иткән очракта гына үз-үзен аклый ала. Бу дәүләт органнары эше түгел, интеллектуаль элита функциясе.

Шведлар үз илләрендәге муллыкның мобиль телефон кебегрәк ачышларга нигезләнүен яшермиләр. Ачышлар илне туйдыра, чөнки икътисад, технология, мәгариф шулай оештырылган ки, уйлап табу белән шөгыльләнү отышлырак.

ТФА бу сорауларга җавап табарга тиеш. Хикмәт акча белән тәэмин ителештә дә, штат санында да түгел, ә интеллектуаль һәм административ кодрәттә. Республиканың стратегиясе фәнни даирәләрдә билгеләнергә, ә дәүләт органнары аны республиканың гамәли мөмкинлекләренә яраклаштырырга тиеш.

ТФА татар культурасы үсеше мәсьәләләре буенча вакыт-вакыт яңа идеяләр ташлый. Әмма ул — академия учреждениесе. Аның өстенлекләре дә, кимчелекләре дә шунда.

Заман татар университеты ачуны таләп итә. Татарларның үз университетлары булырга тиеш, ул халык мәнфәгатьләрен чагылдырырга, яңа идеяләр табарга һәм аларны тормышка ашыру өчен кадрлар әзерләргә тиеш.

Татар университеты ачу турында карар бар, әмма моны аклый торган концепция төзү мәгъкуль. Әгәр дә сүз нинди телдә укыту турында гына барса, педагогия университетын киңәйтү белән генә дә чикләнеп булыр иде. Хикмәт башкада. Татар университеты дөнья стандартларына юнәлдерелергә тиеш. Ул халыкара университет булырга тиеш. Халыкка ул дөньяның иң яхшы университетлары белән хезмәттәшлек иткән очракта гына кирәк булачак бит.

Шул ук вакытта татар университеты үзен гамәлгә куйганда, Фәннәр академиясенә таянырга тиеш. ТФАнең Тарих институтында көчле тарихчылар җыелган, ләкин алар укытмыйлар, бары тик китап язу белән генә мәшгуль. Башкалар укыталар, гәрчә шушы институт кешеләре язган китаплар буенча булса да. Бу дөрес хәл түгел. Кадрларны фәннең алгы сафында баручы галимнәр әзерләргә тиеш. Бүтәнчә әйтсәк, академия институтлары яңа университетта үз кафедраларын ачарга тиеш. Моның белән ике мәсьәлә хәл ителә: университетның конкуренциягә сәләте бердән артачак, ә академиягә яңа сулыш өреләчәк, чөнки ул республика һәм татар халкы үсешенең конкрет мәсьәләләрен хәл итүгә катнашачак.

Нәкъ менә шушы татар университеты киләчәктә татар халкы һәм республика өчен яңа идеяләрнең төп чыганагы була ала һәм булырга тиеш тә.

Культура — очсыз-кырыйсыз дәрья, аңа хезмәт күнекмәләре дә, кеше җанының психологик нечкәлекләре дә, кешенең табигатькә мөнәсәбәте дә — һәммәсе дә бергә җыелган. Аны иңләр өчен күз күреме дә, сүз кодрәте дә җитми, аны тоя белергә генә кирәк. Халыкның көче, рухи ныклыгының сере нәкъ менә культурада инде.

Татар, синең байлыгың — синең культураң ул. Нефть тә, заводлар да, мал-мөлкәт тә түгел — культура, бары тик культура.

Культурадан кадерлерәк бернәрсә дә юк һәм бу тормышның культураны үстерүдән гайре мәгънәсе юк.

Безнең халык тарих тегермәнендә күп тапкырлар тартылган инде, зыялылар буыны-буыны белән юкка чыгарылган һәм халыкта яңадан туар көч тә калмаган кебек тоелган. Ләкин гомер узган, яңа шагыйрьләр һәм язучылар, драматурглар һәм җырчылар туа торган. Алар культурадан көч алганнар.

Мәдәният — көч вә илһам чишмәсе. Мәдәниятне үстерсәк, халкыбыз да яшәр.

## V. «Зур Татарстан»

Быел булачак халык санын алу турында бәхәсләшкәндә, мин Русия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институты директорыннан болай дип сорадым: «Халыкларның алфавит буенча сез төзегән исемлегендә татарлар һәм Казан татарлары аерым язылган. Сез аларны нинди билге буенча аерасыз? Инде мин кайсына язылыйм — татаргамы яки Казан татарынамы?» Ул миңа, һич уңайсызланмыйча: «Үзегезне кем дип хис итәсез, шулай язылыгыз»,— диде. «Мин бит үземне юләр дип хис итмим»,— дип җавапладым мин.

Русия галимнәре аңгыра түгел, сүзнең ни турыда икәнен яхшы аңлыйлар. Ләкин заказ заказ инде. Фәнни принципларда эшләсәләр, алар урыс милләтен дә, алфавит буенча исемлек төзеп, казакларга, Мәскәү урысларына, поморларга, урысларга, сибирякларга бүлгәләп куярлар иде. Халык санын алуга әзерлек үзәкнең татарларны бүлгәләргә, шуның белән татарларның санын киметергә чиксез омтылышын фаш итте.

Ни өчен үзәк нәкъ менә бүген кинәт кенә шуның белән шөгыльләнергә булды соң әле? Җавап бик гади. Бер яктан, илдә империячел башлангыч көчәйде. Икенче яктан, татар һәм ислам факторлары көчәйде. Татарларга ирек бирделәр һәм татарлар, шуннан файдаланып, иҗтимагый процессларга йогынты ясый башладылар. Хәзер үзәк татарларны теләсә нинди ысуллар белән туктатырга тырыша, ләкин җен кувшиннан чыгарып җибәрелгән шул инде.

Яшең 55 тән артып барганда үз-үзеңнән сорар чак җитә: син үз халкың өчен нәрсә эшләдең? Халкыңның язмышы хәл ителгәндә, син кайда идең? Синең шәхси өлешең нинди? Авыр сорау, бу тормышта нәрсәдер шәхсән сиңа бәйле булса, бигрәк тә. Тарихны кире кайтарып та, яңадан язып та булмый. Яхшымыначармы — ул инде яшәлгән гомер…

Милләтне тел, культура, рухи кыйммәтләр берләштерә. Ләкин хәзерге заманда дөньяны акча, мәгълүмат һәм хакимият хәрәкәткә китерә.

Татарлар акча эшли беләләр. Әмма аларның байлыгы халыкны берләштерүче фактор була алдымы? Юктыр, мөгаен. Байлар бит ярлылар проблемаларыннан ихаталарының биек коймалары һәм машиналарының караңгы тәрәзәләре артына кереп качтылар. Ахыр чиктә нииндидер сәдака биреп котылу ягын карыйлар.

Нәрсә соң ул байлык? Беркатлы сорау кебек тоела. Бай ул — акчасы, өч катлы йорты, джипы яки «Мерседес-600»е булган кешедер, күрәсең. Ә инде тирәнгәрәк күз салсаң, байлык белән байлыкның аермасы күренәчәк: үзең өчен байлык һәм башкалар өчен байлык. Биредә хикмәт хәйрия гамәлләрендә генә түгел.

Швейцария биләмәләре ягыннан Татарстаннан бераз кечерәк, әмма ул — дөньяның иң бай һәм иң абруйлы илләреннән берсе. Нефте һәм башка табигый байлыклары булмаса да, бу ил акча эшли һәм аннан файдалана белә. «Яңа урыслар» акчаларын шунда саклый. Кайчандыр Швейцария хәерче ил булган, аның гражданнары эш эзләп хәтта Русиягә кадәр килеп җиткәннәр — швейцар булып эшләгәннәр.

Швейцариянең тормыш муллыгы экономияләүгә нигезләнгән. Кыйммәтле машина анда әдәпсезлек булып санала. Хәтта дәүләт учреждениеләре дә үзләренә мондый чыгымнарны рөхсәт итмиләр. Баш шәһәрләре Берндa исә федераль хөкүмәтне саклаучы куркынычсызлык хезмәткәрләре тау велосипедларында йөри. Министрлар, хәтта ил буйлап рәсми делегацияләрне озатып йөргәндә дә, электричкаларга утыра. Ләкин анда мәгарифкә акча кызганмыйлар, чөнки аларны белем баета. Швейцариядә берәр «Мерседес» күзгә чалына икән, димәк, бирегә «яңа урыс» килеп төшкән.

Татарстан Президенты район хакимияте башлыкларын киңәшмәгә җыйса, Кремль дөньяның иң дәрәҗәле һәм иң кыйммәтле машиналары күргәзмәсенә әверелә. Ә бит район хастаханәсен рәткә кертү өчен бер джип кына да җитә ләбаса.

Стэнфорд университеты чакыруы буенча мин берничә тапкыр Калифорниядә булдым һәм андагы миллионерларның Сан-Франциско тирәсендәге шәһәрчекләрен күрдем. Анда миллионерлар бер катлы йортлар салалар, чөнки алар арзангарак төшә.

Казан тирәсенә дә сарайлар салына, аларны җылыту өчен пенсия генә түгел, гади гражданның хезмәт хакы да җитми. Ул гына да түгел, безнең миллионерлар, акчаларын кая куярга белмичә аптырап, шул ук стильдә икенче, өченче коттеджларын төзеп куялар.

Италиялеләр — искиткеч аш осталары. Дөньяның иң яхшы рестораннары аларныкы, Италиянең үзендә бигрәк тә. Римда да, башка кечкенәрәк шәһәрләрдә дә мәҗлесләрдә булырга туры килде. Һәрбер җирдә ризык затлы, ләкин беркайда да бездәге кебек сыйдан өстәлләр сыгылып тормый. Алар ризыкның ашалмыйча калуын яратмыйлар — культуралы җәмгыять өчен бу әдәпсезлек санала.

Коръәндә болай дип язылган: «Исраф итүче — Иблис туганы…» Татарның тышкы байлыгы — рухи ярлылыгының капма-каршы ягы.

Соңыннан бер атналык ризыгы кала торган мәҗлес нигә кирәк? Өч кешелек гаилә өчен күпкатлы зур коттедж нәрсәгә? Заманча, арзан машиналар булганда, «Мерседес» ни эшкә? Ахыр чиктә, барлык машиналар да чүплеккә эләгә ләбаса. Акчаны балаларга белем бирүгә, халкыңны берләштерергә ярдәм итә торган

инфраструктураларны үстерүгә, яңа эш урыннары булдыруга, үзеңне генә түгел, башкаларны да баета торган технологияләр уйлап табуга тотарга кирәк. Тормышның мәгънәсе — үз халкыңа хезмәт итүдә, калганы барысы да фани һәм вак-төяк.

Дөньяда иң бай кеше — Билл Гейтс. Ул бөтен кешелекнең яшәү рәвешен үзгәрткән технологияләр уйлап тапкан. Аның байлыгы акча түгел — интеллект җимеше. Студент Билл Гейтсның шәп идеядән гайре бернәрсәсе дә булмаган. Ә бүген без аның компьютер программаларыннан файдаланабыз, алар һәрбер өйгә кергән һәм һәрберебезне рухи яктан да, матди яктан да баета.

Башкаларны баета торган байлык кына чын байлык була.

Безнең эшкуарларның байлыгы нинди технологиягә корылган соң? Бу сорау, әлбәттә, риторик. Аның җавабы һәрберебезгә мәгълүм. Әмма әдәпсез булыр иде. Бездә байларга һәм ярлыларга бүленү берәүләрнең акыллы, ә икенчеләрнең ахмак һәм булдыксызлыгы аркасында түгел, бөтенләй башка сәбәпләр аркасында килеп чыккан…

Бай ил байлар күп булган ил түгел, ярлылар булмаган ил. Цивилизацияле илләр үзләрендә фәкыйрьләр юклыгы белән горурлана, экономияләү һәм милекне нәтиҗәле файдалана белү исәбенә үсешкә ирешәләр.

Чамадан тыш чыгымнарга корылган бизнес һәм культура үсешенә ярдәм итмәүче биналар — үле капитал. Үз республикаң һәм үз халкың үсеше өчен тотылмаган акча — үле акча. Берәүне дә баетмыйча тик торган милек — үле милек. Казан тирәсендә һәм шәһәр эчендә үле капитал зоналары җитәрлек — коттеджлар, буш биналар, чүп баскан җирләр. Тимер юл буйлап тау-тау чүп өелгән. Шәһәр үзе үк бер чүплек сыман. Һәм бар җирдә — коймалар, коймалар һәм коймалар, байларны яшереп ятучы биек таш коймалар һәм коточкыч мескен ишегалларын каплап торучы кыйшаеп беткән җимерек агач коймалар. Ә шушы урамнардан, чокыр-чакырдан суперкыйммәтле джиплар чаба. Күңел әрнетерлек күренеш.

Үзең ярлы булып, байларны өйрәтеп яту җиңел, әлбәттә.

Хакимияткә якын булсаң, тәнкыйть угы үзеңә төбәлә. Дәшмәвең хәерлерәк, чөнки «хакимият икәнсең — тот та үзең эшлә!» диячәкләр. Кешеләрдә бит һәркем алдында бурычлы саналган һәм бар нәрсәне булдыра ала торган дәүләткә совет чорларыннан калган сукырларча табыну яши. Озакка сузылачак хата фикер бу. Күндәмлек һәм хакимият механизмнарының чиксез кодрәтенә ышаныч — милләт өчен куркыныч нәрсә.

Дәүләтчелеккә ирешү соңгы ун ел эчендә иң мөһим тема һәм сәясәтебезнең иң зур казанышы булды. Дәүләт суверенитеты өчен көрәш, Шартнамәгә кул кую, көчле тышкы сәясәт, һәм, ниһаять, хакимияткә Путин килгәч, үз хокукларыбызны яклау — мондый данлы юл белән горурланырга мөмкин. Ләкин күпләр Татарстанны ныгыту белән халыкның барлык проблемалары хәл ителер дип уйлаганнар иде. Әгәр дә татарларның күпчелеге республикабызда яшәсә, шулай булыр да иде, мөгаен. Әмма бүген татарларның башка төбәкләрдә дә яшәвен исәпкә алырга кирәк, алар анда бары тик үз көчләренә генә таяна алалар.

Русиядә татарларга мөнәсәбәт бервакытта да гади булмады, киләчәктә дә аның яхшыруы көтелми. Империяләр үзләренең үткәне белән тыныч кына хушлаша алмыйлар. Таркалганда алар сасы ис тараталар. Димәк, язмышның теләсә нинди борылышына әзер булырга кирәк.

Патша Русиясендә, каты басымга карамастан, татарлар икътисади структураларны, мәгариф системасын үстергәннәр, сәяси партияләр оештырганнар. Татарның тормыш авырлыкларына чыдамлык запасы зур булган. Совет системасы, СПИД шикелле, күпләрне иммунитеттан мәхрүм итте. Ә бит халыкның исән калуы өчен иң мөһиме — үз-үзен оештыру сәләте.

Башкортстан татарларының Казанга килеп язмышларыннан зарлануын күрү авыр, гәрчә миллионнан артык булсалар да. Бу бит бик зур көч. Эстонлылар әнә җир йөзендә дә нибары бер миллион.

Татарлар дөньяга аваз салдылар салуын, ләкин шул ук вакытта күп мәсьәләләрдә җитлекмәгәнлек күрсәтәләр, Татарстанның башкарма структураларыннан үз проблемаларын хәл итүне таләп итәләр.

Республика татар мәгарифе һәм культурасы үсеше өчен җаваплы, чөнки әлеге функцияләрне үтәрлек гомумфедераль яки башка структуралар юк. Ләкин Татарстанның бюджет мөмкинлекләре чикле. Алар белән ерак китеп булмый. Димәк, балаларга өстәмә белем бирү турында милләт үзе кайгыртырга тиеш. Татар юнәлешле Интернет-белем хәзерге ихтыяҗларны күпмедер дәрәҗәдә канәгатьләндерергә мөмкин. Татарстан югары уку йортларының татарлар күпләп яшәгән җирләргә үтеп керүе дә яхшы булыр иде, ләкин бу бик катлаулы процесс, аның ике яклы булуы зарур.

Татар дөньясы үткән заманнарда гәзитләренең күплеге белән аерылып торган. Без моның белән һәрвакыт горурлана килдек, ләкин бүген әлеге тармакның әллә ни перспективасы юк. Гәзитләр язылу ысулы белән генә тираж җыя алмыйлар, иганәчеләр ярдәме кыйммәткә төшә һәм, иң мөһиме — нәтиҗәсе аз. Ул мәсьәләне асылда хәл итми. Чагыштыру өчен: совет чорындагы берничә татар гәзитенең гомуми тиражы 3 млн. нөсхәгә җитсә, бүген исә аларның саны, шактый артуга карамастан, гомуми тираж 0,5 млн. нөсхәдән дә ким. Киләчәктә электрон мәгълүмат чаралары, һичшиксез, өстенлек алачак.

Интернетта электрон газеталар ачу җиңелрәк тә, арзанрак та, кирәк булса, аларны теләсә кайда бастырып алырга була.

Федераль хөкүмәт «Голос России» радиостанциясен безнең салымнар исәбенә тота, ул 32 телдә дөньяның 160 илендә сөйләп тора. Ләкин ничә мәртәбәләр мөрәҗәгать итүгә карамастан, татар телендә тапшырулар башлаудан баш тарта. Без Русия өчен чит-ят. Русиянең федераль хезмәтләре белән эш итүгә караганда Американың «Свобода» радиостанциясе белән уртак тел табу җиңелрәк булып чыга.

Татарстанның кыска дулкынлы радиостанциясе гомумтатар мәгълүмат киңлеге проблемаларын өлешчә хәл итәчәк, ләкин өлешчә генә. Җирле FM станцияләренә исәп тоту мәгъкуль, аларны хәлле эшкуарлар үзләре дә ача ала. Татарча тыңлаучылар күп булган җирдә, мәсәлән, Мәскәүдә, аларны матди зыянсыз эшләтү мөмкин, ә инде Интернетка тоташтырсаң, аудитория тагын да киңәя.

Телевидениенең бүген конкуренты юк. Татарстанның «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе үз тапшыруларын спутник каналы буенча тапшыра башлады инде. Әмма хәзергә бу беренче кыюсыз адымнар гына. Әлегә ТНВ каналының бөтен татар дөньясына ничек итеп эшләячәген ачык кына күзаллап булмый. Аны төрле өлкәләрдә кабул итү даирәсе телевизор караучыларның матди мөмкинлекләре белән чикләнә. Бу юнәлеш искиткеч перспективалы. Аның әһәмияте гаять зур. Мәгълүмат өлкәсендә татарлар өчен спутник телеканалыннан да мөһимрәк нәрсә юк, шуңа күрә аны ныгыту өчен көч тә, акча да кызганмаска кирәк.

Татарларның Русиядәге чын абруен өч фактор билгеләячәк: Татарстан Республикасын ныгыту, милли-мәдәни автономияләрнең оешканлыгы һәм мөселманнарның бердәмлеге. Әгәр дә шушы өч факторны бер йодрыкка төйни алсак, Русиядә бер генә җитди мәсьәлә дә татарлардан башка хәл ителмәячәк.

Татарларның федераль хакимияткә бәйләнмәгән үз гомумрусия партиясе булырга тиеш. Ул сәяси технологлар ялганыннан ерак булырга, татар мәгълүмат челтәренә таянырга, үз эчендә этник һәм ислам факторларын берләштерергә, Русиянең башка халыкларын да үзенә тартырга тиеш. Революциягә кадәр шулай булган, киләчәктә дә шулай булыр.

Хакимият күп нәрсәне билгели, Русия кебек илдә бигрәк тә. Ләкин нәкъ менә Русиядә хакимияткә иң аумакай сәясәтчеләр ыргыла. Бүгенге партияләрнең әһәмияте аз, хәер, чын партияләр юк та. Үзәк хакимият сәяси оешмаларны үз белдеге белән оештыра, аларны теләгәнчә хәйләли, кирәкләре беткәч тарата. «Единая Россия» партиясенең төп документлары әзерләнгәндә (сүз уңаеннан, төзелеше ягыннан бу партия — МЧС клоны), аларда халыклар һәм федерализм турында бер кәлимә сүз дә юк иде. Минтимер Шәймиев һәм Олег Морозов басымы астында андый бүлек барлыкка килде. Үзәктә аек акыл белән гомумкешелек кыйммәтләрен түгел, басым белән көчне генә таныйлар. Чөнки Русия инстинктлар әсирлегендә яши, ә инстинктлары — империячел.

Без әхлаксыз сәяси технологияләр хакимлеге чорында яшибез, алар өчен бернинди чикләр дә, бернинди изге нәрсә дә юк. Дөньяга караш һәм милли идея кебек гаять мөһим нәрсәләрне хакимияткә омтылу дәрте алыштырды. Хакимиятне акчага сатып алалар, ә хакимияттән исә акча ясыйлар.

Мондый «сәясәткә» каршы тору кыен, чөнки аңа каршы торучыларның принциплары һәм әхлакый нормалары бар. Аларның көчсезлеге дә нәкъ менә шунда шул. Әмма сәяси технологлар якындагы конъюнктурага юнәлеш тота, аларны илнең һәм халыкның, бигрәк тә Русия халыкларының киләчәге кызыксындырмый һәм кызыксындыра алмый да. Алар кыска вакыт эчендә хакимияттән мөмкин булганның барын да сыгып алырга омтылалар. Тизрәк баеп калырга телиләр, ә моның өчен акча агымнарын үзәкләштерү кирәк. Әгәр әлеге максатка ирешү өчен сугыш кирәк була калса, алар сугыш ачалар, әгәр тагын бер дефолт кирәк дип уйласалар, анысын да оештыралар.

Күпләр сугыш каядыр еракта бара, ул чын сугыш та түгел, террорчылыкка каршы чара күрү генә дип уйлыйлар. Сәясәтчеләр фикеренчә, әгәр телевизордан сугыш хәрәкәтләрен күрсәтмәсәң, бернинди дә сугыш юк дигән сүз. Чынлыкта исә, Чечняга ташланган бомбалар Русиянең һәрбер шәһәрендә шартлап тора. Алар безнең йөрәк түрләребездә шартлап, җәмгыятебезне җимерәләр. Мондый сугышта бары тик җиңелүчеләр генә була. Ни чәчсәң, шуны урырсың, ди халык. Сәяси технологлар чикләнгән дип саналучы гражданнар сугышы чәчтеләр, димәк, бөтен ил буйлап фашизм урып җыячаклар. Бу — империянең үлем ачысы.

Бөтен нәрсәне үзәкләштерү һәм бердәйләштерү процессы Русияне җимерә бара. Үз тарихында Русия каты куллы үзәкләштерелгән идарә системасын ике тапкыр төзегән иде инде. Беренче тапкыр — крепостное правоны бетергәннән соң, нәтиҗәсе — революция. Икенче тапкыр — коммунистлар планлаштырылган икътисад һәм гражданнар белән матбугат өстеннән бертуктаусыз күзәтчелек итүче дәүләт төзегәннәр иде. Нәтиҗәсе — «үзгәртеп кору» һәм СССР таркалу. Русия үзе сөяп куйган тырмасына үзе үк өченче тапкыр баса. «Хакимият вертикале» — харакири бит ул. Федераль хакимият гаҗәеп үҗәтлек белән үз-үзен үтерүнең шушы коточкыч ритуалын дәвам итә.

Үзәк хакимият республикалар белән көрәшәчәк, аларны административ территорияләргә әйләндерергә, ә халыкларга, соңыннан әкренләп юкка чыгару өмете белән, милли-мәдәни автономияләрне калдырырга тырышачак. Сәяси технологлар Казан оештырганның барысын да нейтральләштерү өчен параллель һәм альтернатив татар хәрәкәтләре булдырачаклар. Татарстан Конституциясенең яңа редакциясен яхшылап «манчыячаклар». Ахыр чиктә, динебезнең йогынтысын чикләү өчен, исламга ябырылачаклар. Дәүләт Думасының татарның латин графикасын тыюы— законлаштырылган бөек державачыл шовинизм. Вакыт җитте — чаң кагалар.

Урыс җаны соңгы гасырларда Көнбатыш белән Көнчыгыш арасында бәргәләнде. Ул Көнчыгыш традицияләреннән дә китә алмый һәм Европаның бер өлеше булырга да теләми. В.Путин җәмгыятьне Көнбатышка һәм НАТОга каршы котырткannaн соң, кинәт кенә һич көтмәгәндә НАТО белән берләште дә, СССР һәм Русиянең барлык лидерлары арасыннан Көнбатыш яклы иң шәп җитәкче булды да куйды. Ләкин аның Аппараты татар теленең латин графикасына кискен рәвештә каршы килә. Бер үк вакытта Көнбатыш яклы һәм латинга каршы булу мөмкин хәл түгел. Бу шизофрения дип атала. Сәяси технологлар Русия җәмгыятен шизофрения хәленә китереп җиткерделәр.

Мондый вазгыятьтә гадел сәясәт алдан ук оттыруга дучар. Гадел сәясәткә өндәү утопия сыман тоелса да, халыкның стратегик мәнфәгатьләрен гамәлләштерү күзлегеннән караганда, ул — бердәнбер мөмкин чара. Гадел сәясәтнең гаять зур өстенлеге бар — киләчәктә бары тик гадел сәясәт кенә җиңә ала. Ә сәяси технология конъюнктурага корылган, ул — көнлекче хакимнәр өчен генә. Ахыр чиктә, без кая китик тә ни эзләп китик? Без үз җиребездә яшибез һәм безнең Швейцария банкларында акчаларыбыз да юк.

Урысларның мәңгелек бер сораулары бар: «Нәрсә эшләргә?» Татарларда ул башкачарак яңгырый: «Татар халкы үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» Бу сорауга төрлечә җавап биргәннәр. Иманым камил: татар үлмәгән дә, йокламый да. Ул көч җыя. Аның үсеш нокталары бөтен ил буйлап чәчелгән. Ыңгырашудан һәм зарланудан туктаган кешеләр дә барлыкка килде бит. Алар булдыра алганча хезмәттә. Инде аерым учакларны бер куәтле ялкынга әйләндерергә вакыт. Һөҗүмгә күчәр чак җитте. Заман гомумтатар һәм республика структураларын үзара ныграк бәйләүне таләп итә.

Без тарихи борылыш алдында торабыз, без, сыйфат ягыннан ыргылыш ясап, «Зур Татарстан» оештырырга, ягъни республиканың дәүләт структураларын татар халкының рәсми оешмалары белән берләштерергә тиешбез. «Зур Татарстан» тирәсендә иҗтимагый оешмалар, мәгълүмат чаралары, икътисади һәм башка структуралар тупланырга тиеш. Финанс, хакимият, мәгълүмат, интеллектуаль һәм башка ресурсларны берләштерү безне алга этәрәчәк һәм татарның потенциалы кискен артачак.

Татар мәгарифе һәм мәдәнияте системасын килештерү функциясе, нигездә, республика оешмалары җилкәсенә төшәчәк. Нәтиҗәлелекне арттыру өчен аларның үзләрендә тиешле бүлекләр кирәк булачак. Ягъни мәгариф, мәдәният, яшьләр эшләре буенча министрлыкларда тулаем татар халкын үстерү системасы өчен генә җавап бирүче министр урынбасарлары билгеләргә кирәк. Әлеге урынбасарлар, вице-премьер җитәкчелегендә һәм ТР Дәүләт Советының мәдәният мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе, федераль милли-мәдәни автономия җитәкчесе белән бергәләп, «Зур Татарстан хөкүмәте» тәшкил итәрләр иде. Сүз уңаеннан, матбугат битләрендә татар латинына күчүгә бәйле рәвештә республиканы үзенең тар мәнфәгатьләрен яклауда гаепләп чыктылар. Мондый «хөкүмәтнең» булуы киләчәктә Татарстанны мондый гаепләүләрдән коткарыр иде, ичмаса.

Бу «хөкүмәт»кә ике төп көч ярдәмгә киләчәк — «Яңа гасыр» (ТНВ) телеканалы һәм Интернет.

90 нчы еллар уртасында бер гәзит мине «Кремль хыялые» дип атаган иде. Әле язганнарымның да күбесе фантазия яки хыял кебек тоелуын мин яхшы аңлыйм. Бу мәкаләне укыгач, тәнкыйть тарафдарлары куана-куана эшкә тотыначак. Алар арасында акча өчен Татарстан турында теләсә нәрсә язарга әзер булганнары да, болай гына тәнкыйтьләргә яратучылары да бар. Тәнкыйть хакына тәнкыйть, оппозиция хакына оппозиция. Холыклары шундый. Алар хакимиятне хакимият булган өчен генә тиргиләр. Сүз уңаеннан, бу — либераль интеллигенциянең чиста урыс традициясе.

Татарстанның суверенитеты өчен хәрәкәт башлаганда, безнең уңышка ирешәчәгебезгә ышанучылар сирәк иде. Ул чакта, 1988 елда, татар телен республиканың барлык мәктәпләрендә, хәтта вузларда укыта башларлар, Татарстанның дистәләгән чит илдә үз вәкиллекләре булыр, Казан Кремлендә дүрт гасырдан артык торган гарнизон чыгарылыр да аның урынында Кол Шәриф мәчете төзелер дип уйларга мөмкин идемени? Казан Кремлендә хәрби плац урынына мәчет?! Хыялның да нинди әле! Әмма бүген, иншалла, анда мәчет балкып тора.

Илдә бурлар, коррупционерлар һәм сәяси технологлар җыен ясап, шуның белән мактанып, намуссызлыкны дәрәҗәгә санап ятканда, халыкка хезмәт итәргә өндәү — үзе дә утопия. Законсызлык һәм башбаштаклык хакимлек иткән илдә гадел сәясәт турында бары тик хыялый кеше генә сөйли ала. Чынлыкта исә,

бу фантазия дә, хыял да түгел, ә бәлки, дистә ел актив сәяси эшчәнлек дәверендә барлыкка килгән позиция. Шул ялганчылар сафына басып булмый бит инде! Бу үз үлемеңнән дә куркынычрак рухи үлемгә тиң нәрсә.

Нәрсә генә булмасын, ни генә сөйләмәсеннәр — халык һәм республика мәнфәгатьләреннән дә югарырак барыбер бернәрсә дә юк. Бу тормышның башка мәгънәсе дә юк. Калган барысы да — ыгы-зыгы, вактөяк, ә ыгы-зыгы, мәгълүм ки, шайтаннан килә.

Җәмгыятькә хезмәт итмәгән алтынның мәгънәсе юк. Хакимиятнең дә, диннең дә үзкыйммәте бар. Байлык берләштерергә тиеш. Дин һәм тарих, культура һәм тел халыкны берләштерергә һәм аның дәрәҗәсен күтәрергә тиеш! Татарлар дөньяның алга киткән халыклары белән бертигез булырга тиеш. Яшәешебезнең мәгънәсе менә шунда.

Иректән дә кадерле нәрсә юк. Ул алтыннан да, хакимияттән дә, дәүләтнең теләсә нинди мәнфәгатьләреннән дә югарырак.

Мин әле тагын бу планетадагы иң соңгы империянең кайчан да булса, ниһаять, юкка чыгуы турында хыялланам. Империя җимерелергә тиеш. Русиядә демократия, федерализм, хәбәрдарлык, тынычлык һәм халыклар иреге тантана итәргә тиеш. Моның хакына яшәргә дә, хыялланырга да ярый.

Ә бәлки, боларны исән чакта күрә дә алырбыз? Татарлар бердәм булса, әлбәттә, күрәчәкбез! Татарда мондый мәкаль бар: «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар».

Андый хәлгә калмыйк!

## КАЙДА БЕЗНЕҢ КЫЙБЛА?

*(Евроислам манифесты)*

> *«Зан итү, ягъни дәлилсез уйлау, яки нәфес теләгәнчә хөкем итү — дөреслекнең һичбер өлешенә ирештермәс»* [10:36].

инем әби динле кеше иде. Көн саен биш вакыт намазын калдырмады, ураза тотты, дуңгыз ите ашамады. Кечкенә чагымда кичләрен миңа әкият урынына пәйгамбәрләр тарихын укый иде. Казан университетының физика факультеты студенты булгач, мин кайчак аңа Коръәннең кайбер катлаулы сүрәләренә төшенергә ярдәм итә идем. Коръәннең урыс теленә И.Ю.Крачковский тәрҗемә иткән вариантын алып, үзем өчен ят темаларны әбиемә булдыра алганча татарча аңлатырга тырыша идем.

Безнең буынны диннән мәҗбүри аердылар. Физика факультетында акыллы яшьләр укый, алар квант механикасы, синхрофазотроннар, атом таркату дөньясында яши иде. Без Лобачевский геометриясен аңларга тырыша идек. Аның буенча, ике параллель сызык йолдызларның һәм планеталарның гравитация кырлары ергалап бетергән очсыз-кырыйсыз Галәмнең кайсыдыр бер ноктасында кисешергә тиешләр. Япь-яшь Роальд Сәгъдиев безгә килеп атом-төш синтезы турында лекцияләр укый иде. Физика фәне материянең иң катлаулы законнарын аңлата ала сыман тоела иде. Аллаһы Тәгалә исә дәлилләрнең мантыйкый чылбырында артык буын итеп кабул ителә, аны шул, һич югы, кеше тарафыннан танылып җитмәгән билгесезлеккә кайтарып калырга була иде. Альберт Эйнштейн — менә кем иде безнең алла.

Бервакыт мәшһүр физиклардан берсенең диндар кеше булганлыгын белеп, мин бик каты гаҗәпләнгән идем. Атом һәм водород бомбалары ясау белән Коръән яки Библия уку арасында һичнинди бәйләнеш күренми иде.

> *«Дәхи Раббыңнан яшерен булмас җирдә вә күкләрдә тузан бөртеге хәтле нәрсә, ул нәрсә кирәк — тузан бөртегеннән зур булсын, кирәк — кечкенә булсын, барчасы өммүл-китапта язылмыш»* [10:61].

Атомның чиксез таркалышын, берни белән дә чикләнмәгән Галәмне күзаллау, башы да, ахыры да булмаган вакытны аңлау бик кыен. Мондый төшенчәләрне без йә кире кагарга, яисә аксиома итеп кабул итәргә тиеш. Аларны акылга муафыйк рәвештә аңлатып бирү мөмкин түгел, чөнки безнең тормыш тәҗрибәсе моңа каршы килә һәм әлеге күзаллаулар белән килешми. Биредә интуиция, ягъни тоемлау да ярдәмгә килә алмый. Чиксезлеккә бары тик ышанып кына була.

Атомны тәшкил итүче кисәкчекләрне хәтта электрон микроскоп аркылы да күреп булмый, алар махсус приборда үз эзләрен калдырып кына беленәләр. Кисәкчекләр бильярд шары кебек тотып, үлчәп карап була торган объектив җисем түгел, алар — «нәрсәнеңдер» прибор белән үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсе. Өстәвенә без бу «нәрсәнедер» җисем дип тә, дулкын дип тә атый алмыйбыз, чөнки ул бер үк вакытта җисем дә, дулкын да. Безнең дөньяда үзара сыешмаган нәрсәләрнең башка дөньяда сыешуы мөмкин булып чыга. Әм-

ма кисәкчекләрнең ниндидер фантазия, интеллектуаль акыл төзелмәсе, прибордагы ниндидер эзләр дип кенә раслау да дуамаллык булыр иде. Атом бомбасы шартлагач, әлеге кисәкчекләрнең коточкыч чынбарлык икәнен барыбыз да аңлыйбыз.

Гомумән әйткәндә, безнең тормышта бик күп нәрсә — кешенең «объективлык» белән үзара йогынтысы нәтиҗәсе. Кеше, тарих барышына катнашып, бу мәгънәдә тарихны үзе ясый да. Хакыйкать катып калган абсолют нәрсә түгел, ул безнең үзебезгә бәйле. Фәрит Исак дөрес кисәтә: «Ләкин минем проблема исламнан безнең күпме һәм нәрсә алуыбызга бәйләнмәгән. Хикмәт башкада: без аңа үзебез ни дә булса кертәбезме? Һәм без керткән өлеш исламның йөзен ничек үзгәртә ала? Без һәм ислам, чынлап та, бер-берсеннән бөтенләй аерым нәрсәләрме? Ислам бездән башка, үзе генә яшиме? Иман заты үзенә безнең тәҗрибәдән дә берәр нәрсә ала алмыймыни?»

Меңләгән еллар буе иудаизм, христианлык, ислам һәм буддизм аң-белем таратып гуманлык һәм мәрхәмәт хисләре тәрбияләгәннәр. Шуңа да карамастан цивилизацияле кешеләр, ихтимал, Ходай исеме беләндер, тыныч халык өстенә атом бомбасы ташладылар. Аннан соң, тагын да ашкыныбрак водород бомбасы, химик һәм бактереологик корал эшләүгә тотындылар. Нәрсә бу? Шайтан мәкереме? Әйе, болай да аңлатып була, ләкин бу артык гади аңлатма түгелме соң?

Ни өчен Ходай шулкадәр афәтле сугышларга, Җирне тәмугка әйләндерерлек корал уйлап табуга юл куйган? Ул бит барысын да күрә, ул һәммә нәрсәдән хәбәрдар, аның кодрәте киң һәм ул иң мәрхәмәтле.

> *«Әгәр яхшылыктан сиңа бер шатлык ирешсә, ул шатлык Аллаһыдан, әгәр казадан бер кайгы ирешсә, бу кайгы үзеңнең кимчелегеңнәндер»* [4:79].

Совет иле атеистлар иле иде. Социализм үзе үк демократиянең һәм базар икътисадының Көнбатыш моделенә каршылыкны гәүдәләндерә иде. Яхшымы-начармы, әмма без нәкъ менә шул рухи тирәлектә яшәдек. Иисус Христос, Аллаһы Тәгалә, пәйгамбәрләр урынын Ленин алган иде. Без Ленин әсәрләренең 55 томлык тулы җыентыгын, аның «васыятьләрен», бер адым да читкә тайпылмыйча, җентекләп өйрәндек. Аларны мәгънәсенә әллә ни төшенмичә ятлау иң төп идеологик коралга әйләнде. Ленин цитаталарыннан бер генә хәрефкә тайпылган кеше — еретик, ягъни мөртәт булып санала иде.

Дөньяны революцион үзгәрешләр белән тетрәндергән, фашизмны җиңгән, космосны үзләштерүне башлаган ил, хәрәкәтчәнлеген югалтып, «өченче дөнья» исемлегендә булып чыкты. Катып калган фикер һәм авторитетларны аллалаштыру нәтиҗәсе булган фантасмагория иде бу.

Көнбатыш бу вазгыятьтән сабак алды — колонияләренә бәйсезлек бирде, кайбер социалистик идеяләрне үзләштереп, мәгариф системасын үзгәртте, коммунистик куркынычка каршы берләште. Акылга сыймаслык икътисади үсеш, технология, уйлап табулар, ачышлар, тормыш дәрәҗәсен күтәрү Көнбатышны бөтен дөнья өчен үрнәк итте.

> *«Аллаһ берәүне хак юлдан адаштырса, аны туры юлга кертүче, әлбәттә, булмас»* [40:33].

Әбием, үләр алдыннан, үзенең Коръәнен нәкъ менә миңа васыять иткән. Ул моны болай аңлаткан: «Ул китап ярата, димәк, киштәсендә Коръәнгә дә урын табылачак».

Менә Коръән укыр вакыт та җитте...

Исламда яши торган руханилар бар, бу — аларның әлеге дөньядагы вазифасы, эше, хезмәте. Дин — аларның икмәге. Коръәннең, сөннәтнең, хәдисләрнең, шәригатьнең бар нечкәлекләрен аңлаучы галимнәр бар. Аларның тәкъдире — мәсьәләне төрле яктан: аның бар тарихын һәм күпсанлы фикерләрне исәпкә алып шәрехләү, әйтик, ашаритларның язмышның алдан билгеләнү идеясе турында аргументларына, аларның бар нечкәлекләренә кадәр төшенү, мөтәзилитләрнең сайлап алу концепциясен белү. Әмма тормышларын исламга багышламаган, шуңа да карамастан хакыйкатьне үзләренчә эзли торган кешеләр дә бар. Алар Аллаһы Тәгаләгә үз юллары белән баралар.

Бервакыт Насретдин мулла әйткән:

— Мин караңгыда күрәм.

— Яхшы. Әмма, мулла, нигә, алайса, син төнлә шәм яндырып йөрисең соң?

— Башкалар миңа абынмасын дип.

> *«Бәгъзе кешеләр иман китереп изге гамәлләр кылдылар, һичкемгә көче җитмәгән йөкне йөкләмибез, мәгәр көче җиткәнне генә»* [7:42].

Ни өчен ислам дөнья буйлап тиз тарала? Ни өчен Көнчыгыш Көнбатыштан өметсез рәвештә артта калган? Шәригатьнең минем яшәешкә ни мөнәсәбәте бар? 11 сентябрьдән соң дөньяга ни булыр? Бу сорауларга тәгаен генә җавап табу җиңел түгел. Минем фикеремчә, дин белгеченең яки руханиның фәтвасы түгел, Европа белеме алган һәм үз республикасының киләчәген кайгырткан дөньяви кешенең үз фикерләрен кычкырып әйтүе. Барыбызга һәм дә һәрберебезгә кагыла торган проблемаларны кемнеңдер аңлатып биргәнен бер читтә басып көтеп тору мөмкин түгел.

Минем борынгы бабаларым X гасырда үз теләкләре белән ислам динен кабул иткәннәр, аннан соң аны башка халыкларга булдыра алганча таратканнар. XIX — XX гасырларда татарның дин белгечләре исламны үзгәртү юлына басканнар һәм бу юлда күпкә ирешкәннәр. Безнең тарихыбыз бай, ләкин киләчәктә безне нәрсә көтә соң? Мин, билгесезлекне танып белер өчен, һич югы, башкалар миңа бәрелмәсен өчен, шәм яндырып йөрим.

Дин белгече яки имам булмагач, ни эшкә дип кулыңа каләм алдың, диюләре мөмкин. Синең моңа хакың бармы соң? Әмма ислам — ул минем дә асылым, минем дә культурам, әгәр дә мин аны аңларга телим икән, димәк, минем өчен Коръәннән башка чыганак юк. Ни өчен мин кемнеңдер аңлатмасын тыңларга тиеш? Ни өчен Коръәнне үземә укымаска? Хакыйкатькә кемнеңдер монополиясе бармыни? Юк.

Коръәнне аңлар өчен гарәп теленең үзенчәлекләрен һәм нечкәлекләрен белергә кирәк, диләр. Мөгаен, шулайдыр. Ләкин хикмәт шунда ки, бүген Коръәнне оригиналда уку — үзе үк аңлатма бирү дигән сүз, чөнки дәвер дә, кешеләр дә, тел дә, сүзләрнең һәм төшенчәләрнең мәгънәсе дә үзгәреш кичерде. Сүзләрнең дә үз гомере бар. Коръән сүрәләрен ятлау котылу чарасы түгел. Коръән тексты үз тавышы белән сөйләп бирә алмый, аны аңлатучылар кирәк, ә аңлатучылар исә — кешеләр. Һәр кеше, үзенең тормыш тәҗрибәсеннән, культура дәрәҗәсеннән чыгып, үзе укыган сүзгә, аның мәгънәсенә үз күзаллавын сала.

Мөселманнар төрле дәүләтләрдә, төрле шартларда яшиләр. Согуд Гарәбстаны, Иран, Судан илләре бар, алар тарихи шәригатьне саклыйлар. Төркия, Мисыр кебек илләр бар, аларда законнар дөньяви, әмма җәмгыять — мөселман җәмгыяте. Русия һәм Европа бар. Анда мөселманнар христианлык тирәлегендә, азчылыкта яшиләр. Бу тирәлек алар өчен чит түгел, әмма башка тирәлек. Хәлифәтләр заманы узды. Сәид Котб фикеренчә: «Исламны закон итеп танымаган Америкада яки Русиядә иҗтимагый яки икътисади стройга җайлашу өчен ислам кагыйдәләрен булдырырга тырышу шактый мәзәк хәл. Бу бит ислам хакимиятенең өстенлеге танылмаган теләсә нинди илгә кагыла! Фикъһене ислам хакимиятен танымый торган системага буйсындырып үстерергә тырышу һавада орлык үстерергә маташуга тиң, бу — буш гамәл, ул ислам җитдилегенә тормый». Бу татарларны ислам дөньясыннан чыгарып ташлауны аңлатмыймы соң? Европаның елдан-ел арта барган мөселманнарына ни кала? Алар бит үзләрен мөселман дип саный.

Дөнья үзе халыкара хокук булдырган, поликультуралы бердәм бергәлек булып бара. Ул өммәткә әйләнеп бара, чиста мөселман өммәте булмаса да, бердәм өммәт, һич югы, сугыш һәм тынычлык, кеше хокукларын һәм дәүләтләр мәнфәгатен яклау мәсьәләләре буенча бердәм өммәт була бара. Мондый бергәлек Ходай ихтыярына каршы барлыкка килә алмый. Әйтелгән: *«Әгәр Аллаһ кешеләрне якламаса иде, әлбәттә, җирдәге кешеләр һәммәсе һәлак булыр иделәр. Ләкин Аллаһ — барча галәмнәр мәхлугына рәхмәт иясе»* [2:251]. Халыкара оешмалар һәм үзара килешүләр рәвешендәге чикләмәләр дөнья өммәтен барлыкка китерә дә инде.

Өченче меңьеллык кеше һәм җәмгыять каршына бөтенләй яңа таләпләр куя. Шәхес һәм аерым халыкларның роле чагыштыргысыз артты. Алар үзкыйммәткә әверелделәр һәм мөселман берлеге эчендә эреп югала алмыйлар. Дөнья инглиз телендә сөйләшүне кулайрак күрә, балаларыбыз инде Интернеттан чыкмый утыралар. Без үз тормышыбызны дистәләгән каналлы телевидениедән, электрон почтадан, кәрәзле телефоннардан, дөньяның теләсә нинди ноктасына алып бара ала торган самолетлардан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Гарәп теле һәм культурасы элеккеге әһәмиятен һәм күңелгә ятышлыгын югалтты, алар кешегә бернинди дә өстенлек бирмиләр.

Безнең кыйбла кайда соң хәзер?

> *«Пәйгамбәрләрне һәр заманада үз каумләреннән җибәрдек шәригать хөкемнәрен үз телләрендә бәян итсеннәр өчен»* [14:4].

Ислам — борынгы һәм мәңгелек дин. Әйтелгән: *«Ий мөэминнәр, әйтегез: «Аллаһыга һәм үзебезгә иңдерелгән Коръәнгә һәм Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб пәйгамбәрләргә иңдерелгән вәхийгә, аларның балаларына иңдерелгән вәхийләргә ышандык, пәйгамбәрләрне берсен икенчесеннән аермыйбыз, барчасына бертигез ышанабыз, һәм Аллаһыга итагать итеп, мөселман булабыз»,— дип»* [2:135 —137]. Ходай Тәгалә халыкларга дини кануннарны аларга аңлаешлы телләрдә җиткерү өчен дистәләгән пәйгамбәрләр җибәргән.

Гарәпләр кайчандыр беркатлы рәвештә изге китап гарәп телендә иңдерелгән, ә Җәбраил (архангел Гавриил) аны пәйгамбәрләрнең һәрберсенең ана теленә тәрҗемә иткән дип уйлаганнар. Чынлыкта исә Коръән пәйгамбәргә *«иңдерелгән»* [2:285; 3:7; 5:83], *«вәхий кылынган»* [4:163]. Пәйгамбәр әйткән: *«Үзлегемнән Коръәнне алыштырмак яки хөкемнәрен үзгәртмәк миңа һич тә мөмкин түгел, чөнки ул Аллаһ сүзе, мин үзем дә Аллаһ миңа вәхий кылган хөкемнәргә генә иярәмен»* [10:15]. Ходай сүзе барлыкка китерелмәгән, аның тарафыннан әйтелмәгән, әмма аның асылы пәйгамбәр аша җиткерелгән. Әбү Хәнифә: «Аллаһ сөйли, әмма без сөйләгән кебек түгел. Без сөйләм органнары ярдәмендә төрле авазлар чыгарып сөйләшәбез. Аллаһы Тәгалә сөйләменең башы да, ахыры да юк, ул туктап та тормый, чөнки ул хәрефләр дә, авазлар да түгел»,— дип язган.

> *«Аның белән имин булган Җәбраил фәрештә иңде. Ул Җәбраил Коръәнне синең күңелеңә иңдерде, кешеләрне Аллаһ газабы белән куркытучы булмаклыгың өчен»* [26:193—194].

Аллаһы Тәгалә безнең телдәгене түгел, йөрәктәгене тыңлый.

Теләсә нинди телдә сүзләр мәгънәсе аның нинди шартларда яшәвенә бәйле. «Сүзнең мәгънәсе — аның телдә кулланылышы»,— дип язган Людвиг Витгенштейн.

Әйтик, мин «Мелодия волнует душу» дигән җөмләне урыс теленнән татар теленә тәрҗемә итәм ди. Аның төзелеше дә, сүзләре дә гади. Татарча белгән теләсә кем аны шактый тәңгәл тәрҗемә итәчәк: «Моң күңелне дулкынландыра». Инде киресенчә, татарчадан урысчага тәрҗемә итәргә кирәк дип уйлыйк. Менә биредә инде кыенлыклар килеп чыга, чөнки «моң» сүзенең мәгънәсе тирән һәм күптөрле: сагыш, аңлатып булмый торган хис, күңел халәте... Әлеге сүздә татарның драматик, ә кайчак фаҗигале тарихы да, барлык этник кичерешләре дә чагыла. Һәм бары тик ахыр чиктә генә «моң» сүзе «мелодия», ягъни көй мәгънәсен аңлатырга мөмкин. «Мелодичная мелодия» дип тәрҗемә итеп булмый, бу хәтта «душевная мелодия» дә түгел. Бу — татар җанына кагылучы, үзәген өзүче көй. Гомумән, бу гыйбарәне башка телдә аңлату һәм аңлау кыен, чөнки һәрбер халыкның үз тарихы бар. Нәтиҗәдә кире тәрҗемә очрагында баштагы гыйбарәдәге «мелодия» сүзенә урын калмый. «Глубокие душевные чувства волнуют сердце» дип тәрҗемә итүне тәкъдим иткән очракта да, мине «моң» сүзен җиңелчә тәрҗемә итүемне тәнкыйтьләүчеләр табылачак. Һәм алар хаклы булачак. Телдә шушы халыкка гына хас культура стереотиплары яши. Аңыбызда ни булса, әйләнәтирәдә шуны күрәбез. Без ишеткән сүзләр безнең бүгенге күзаллауларны сурәтли.

Мәгънә ул — кулланылыш, шуңа күрә сүзләрнең мәгънәсен кайвакыт үзләре яшәгән шартлар контекстында гына аңлап була. Гарәп өчен дөя — яшәеш, матурлык, муллык, байлык символы. Ул хатын-кызны ана дөягә тиңли ала һәм бу һич тә хурлау түгел. Ә без дөянең мәгънәсенә төшенә алмаячакбыз, чөнки безнең өчен дөя — зоопарк хайваны. Коръәндәге *«Әллә кешеләр дөяләргә карамыйлармы, ничек халык кылынганнар — яратылганнар?»* [88:17] дигәнне укыганда, без бу җөмләнең мәгънәсенә тиз генә төшенә алмыйбыз. Төньяк киңлекләрдә яшәүче кеше өчен дөя — бары тик экзотик хайван гына.

Безгә Коръәндәге, гарәпләр тормышының мөһим нигезен тәшкил иткән *«Инҗир җимеше илә ант итәм вә зәйтүн агачы белән»* [95:1] дигән юлларны да аңлавы читен. Ни өчен шушы агачлар белән ант итәргә кирәк? Аңлашылмый.

Сүзләрнең мәгънәләре бары тик аларны кулланганда гына ачыла. Телдә һәрбер сүзнең мәгънәсе бар, ләкин аның мәгънәсенә ул сүз кулланылган культура контекстында гына төшенергә мөмкин. «Берәр нинди телне күз алдыңа китерү ул — билгеле бер тормыш рәвешен күзаллау дигән сүз»,— дип яза Людвиг Витгенштейн.

Ислам турында хәзерге заман мәкаләләренең берсендә болай диелә: «Кеше Аллаһы Тәгаләгә йөрәге белән якыная. Акыл — йөрәкнең ярдәмчесе». «Йөрәк» (кальб) сүзенең хәзерге замандагы мәгънәсеннән чыгып карасак, бу чыннан да шулай, ләкин Мөхәммәд пәйгамбәр заманында гарәпләрдә йөрәк акыл савыты булып саналган. Димәк, Аллаһка йөрәк белән омтылу, Коръән буенча, аны акыл белән аңлау дигән сүз. Әйтелгән: *«Әллә алар җир өстендә йөрмиләрме, йөресәләр һәлак булган шәһәрләрне күреп гыйбрәт алырлар иде, һәм күңелләре йомшарып Аллаһының газабын аңлар иделәр, һәм колаклары да хак сүзләрне ишетә, йөрәкләре дә аңлый торган булыр иде, бит маңгай күзенең сукыр булуы Аллаһыны танып мөселман булудан мәхрүм итмәс, мәгәр йөрәк сукыр булса, ул мәхрүм итәр»* [22:46]. Биредә «йөрәк аңлый» дип әйтелә, игътибар итегез: без гадәтләнгәнчә йөрәк «тоя» түгел — йөрәк «аңлый». Бүген исә безнең өчен йөрәк акыл савыты түгел, хисләр савыты. Шуңа күрә без Коръәндә *«Аллаһы Тәгалә, бер кешене һидәяткә — диндә туры юлга салырга теләсә, ислам дине өчен аның күкрәген ачып куяр, янә Аллаһ, бер кешене хак диннән адаштырырга теләсә, ул кешенең күкрәген тар, күңелен хактан шикләнүче кылыр, шуннан соң бу кеше, күкрәге тар булу сәбәпле, хаклыктан тыгызланып — Аллаһ хөкемнәрен яратмыйча, гүя күккә чыгардай булыр»* [6:125] дигәнне укыганда, без сүзнең кешенең йөрәге түгел, акылы турында барганын аңларга тиеш.

Гомумән, Коръәндә 133 тапкыр искә алына торган йөрәк турында аерым бер фән барлыкка килгән. Аның зур тарихы һәм күпсанлы юнәлешләре бар. Кешеләрнең һәрбер бергәлеге төрле заманнарда бу сүзгә үз мәгънәсен, кайвакыт капма-каршы мәгънә салган. Димәк, гарәп телен белү Коръән сүрәләрен шәрехләүләрнең барысының да бер мәгънәдә булуларын гарантияли алмый.

> *«Күчеп йөрүче бәдәви гарәпләре әйттеләр: «Иман китердек»,— дип, син әйт: «Сез иман китермәдегез, ләкин мөселманнардан куркып яки мөселманнардан файдаланып, көн күрү өчен тыштан гына ислам динен кабул иттек»,— дип әйтегез! Әле күңелегезгә иман әсәре кергәне юк»* [49:14].

Коръән үзе иңдерелгән культураның һәм халыкларның эзен саклый. Изге китапта мондый сюжет бар: «Кунакларның сүзен ишетеп, Ибраһимның хатыны Сара кунаклар алдына тавышланып чыкты вә йөзенә сугып әйтте: *«Мин бала тапмый торган карчыкмын, миндә кайдан бала булсын»,*— дип» [51:29]. Европа традицияләрендә тәрбияләнгән кешеләр моны сүзгә-сүз аңлый — хатын-кыз үзе үк үз битенә суга. Чынлыкта исә бу хәрәкәт гаҗәпләнүне аңлата һәм ул Көнчыгыш хатын-кызларына хас.

Коръәннең теле сүзгә-сүз укыганда кайбер урыннарда аңлашылмый. Әйтелгән: *«Кеше ашыгучан булып халык ителде! Ий мөшрикләр, газабыбызны сезгә бик тиз күрсәтербез, «газаб булса, тизрәк булсын» дип, мине газабка ашыктырмагыз»* [21:37]. Бу бары тик образ гына, Кыямәт көнен тасвирлау да шундый, анда мондый сүзләр бар: «Кайчан күк ярылса вә йолдызлар чәчелсә...» Аңлашыла ки, йолдызлар чәчелә һәм күкләр ярыла алмый, ләкин шулай хиссиятле сурәтләнгән күренеш кешене ныграк ышандыра. Җәннәт тә әнә шулай образлы итеп тасвирлана.

Хатын-кызның Адәмнең кабыргасыннан яратылуы турындагы легенда, ул сөйләнгән телнең культурасын начар белү аркасында күп гасырлар яшәп килә. Фридрих Макс Мюллер бу турыда болай язган: «Адәмнең Хавага: «Син мин яратылган кебек үк яратылган» дип әйтүе мөмкин, ә борынгы яһүд телендә ул үзенең фикерен «Синең сөягең — минем сөягем кебек, синең тәнең минем тәнем белән бер» («Ты кость от кости моей, и плоть от плоти моей») дип белдергән. Бу гыйбарә берничә буын гына кабатлана, тиздән аннан сүзгә-сүз, кешене ялган мәгънәгә кертүче һәм, болай дияргә мөмкин булса, матди аңлатма килеп чыккан, һәм инде алга таба кешеләр, беренче хатын-кызның беренче ир-ат сөягеннән яки кабыргасыннан ясалуына ышана башлыйлар. Сәбәбе дә гади, күрәсең, Адәм кабыргадан башка яшәүне теләсә нинди бүтән сөякне югалтуга караганда җиңелрәк кичергәндер. Шушы аңлашылмаучылык, бермәлне барлыкка килеп, бөтен сәерлегенә карамастан, сакланып калган». Телдәге шушы клише — ялгышлыкның тотрыклы күзаллауга әйләнеп китүенә бик гыйбрәтле мисал.

Әкиятләштерелгән сюжетларны сүзгә-сүз кабул итәргә ярамый, алар тел сурәтләмәсенең бары тик кайбер элементлары гына. Гасырлар буе яшәү дәверендә исламда бик күп риваятьләр барлыкка килгән, алар, Коръәнгә турыдан-туры карамасалар да, кешеләр аңына шактый нык кереп калганнар.

Безнең тормыш урта гасырлар яшәешеннән тамырдан аерылып тора. Бүген коллык та, баскынчылык та юк, кешеләр кабиләләр тәшкил итми, милләт булып яши. Яһүдләр дә, христианнар да үзгәрде. Өстәвенә Русиядә төрле халыклар яши, биредә икътисад та, климат та башка.

> *«Ул — Аллаһ җирне вә күкләрне хаклык илә яратты, вә Ул кичне-төнне көндезгә кертеп көнне озынайтты, вә көндезне төнгә кертеп төнне озынайтты, вә кояш-айдан кешеләрне файдаландырды, кояш, ай һәм башкалары билгеле көнгә чаклы үз урыннарында йөрүчеләрдер»* [39:5].

Коръәннең кайбер күрсәтмәләре бик катгый язылган, аларны кайбер үзенчәлекле шартларда кулланып булмый. Әйтелгән: *«Һәм сәхәр дә ашагыз, эчегез, хәтта таң яктысы беленгәнче, аннары уразаны тотып, тәмам итегез кояш баеганчы!»* [2:187]. Поляр түгәрәк янында яшәсәң, уразаны ничек тотарга? Анда кояш чыкмый лабаса.

Коръәннең хәрефен генә түгел, рухын да яхшы аңлаган Муса Бигиев, әлеге вазгыятькә үз аңлатмасын тәкъдим иткән. Ул башка бер аятьне анализлаган: *«Ураза саналмыш көннәр, ягъни ураза ае 29 көннән һәм 30 көннән киләдер»* [2:184]. Ул биредә көнне төннән аерып булмый торган географик киңлекләрдә яшәүчеләр өчен күрсәтмә күреп алган. «Озын көннәрдә Рузә» дигән китабында ул болай дип яза: «Изге Коръәннең ап-ачык күрсәтмәсе буенча, мондый төбәкләрдә ураза бервакытта да мәҗбүри түгел. Чөнки ураза билгеле бер сандагы көннәргә генә билгеләнгән, ягъни мәсәлән, көн белән төн үзләренең озынлыклары буенча берберсенә чагыштырмалы булган төбәкләрдә генә. Ә ел бары тик көннән яки бары тик төннән генә торган полюсларда яки Поляр түгәрәк янында, көн дә, төн дә атналарга, айларга сузылган салкын өлкәләрдә яшәүче

кешеләр, көннәрнең вакыт ягыннан чикләнгәнлеге сәбәпле, ураза тота алмыйлар. Бу географик өлкәнең үзенчәлекләреннән килеп чыга». Петербургның ак төннәрен күрмәгән гарәп бу мантыйкны аңламый да, кабул да итми, әлбәттә.

Полюсларда көнчыгыш та, көнбатыш та, зенит та юк, анда кояш чыкмый да, батмый да.

Коръәндә көннең төнгә алмашынуы бер дә үзгәрми торган, үзеннән-үзе аңлашылучы тотрыклы күренеш, ниндидер могҗиза һәм Ходайның барлыгын раслаучы күренеш шикелле бирелгән. Ходай Тәгалә Поляр түгәрәк артында яшәүче кешеләр турында белмәгән дип уйлау да дөрес булмас иде. Ләкин Аллаһ Коръәнне экваторга якын яшәгән гарәпләргә иңдергән, башкача эшләсә, алар моңа инанмаслар иде.

> *«Барча хәлне ачык бәян итүче Коръән илә ант итеп әйтәмен! Без бу Коръәнне гарәп телендә кылдык — шаять, ий кешеләр, аңлап иман китерәсез! Тәхкыйк ул Коръән ләүхелмәхфүздә китаплар анасында сабиттер, сакланадыр. Безнең хозурыбызда, ул гаять бөектер һәм гадел хөкем итүчедер»* [43:2 — 4].

«Коръәндә һәм хәдисләрдә,— дип яза Рукайя Максуд,— кеше хокуклары турында күпсанлы хикмәтле фикерләр бар» һәм ул аларның тулы исемлеген китерә: яшәүгә, тигезлеккә, фикер ирегенә, сәяси ireккә хокук һәм башка хокуклар. Болар барысы да заманча төсмергә ия. Чыннан да, әдәбиятта еш кына мәгълүм хәдистән өземтә китерәләр: «Хокуклар ни рәвешле бозыла? Хокуклар гөнаһлар ачыктан-ачык кылынганда һәм гөнаһ ияләрен ялгышлыктан тыеп торучы булмаганда бозыла». Бу сүзләр без бүген дә куллана торганнарына охшаган, әмма мәгънә башка: йөрәкне әгъза мәгънәсендә дә, җан мәгънәсендә дә бер үк «йөрәк» дигән сүз белән атаган шикелле. «Йөрәк» сүзе кайда да бертөрле языла, ләкин мәгънәсе кулланылган контекстта гына аңлашыла.

Борынгы заманнарда хокуклар ирекле кешеләр өчен генә каралган, колларны кешегә санамаганнар, алар милек булганнар. Мөхәммәд пәйгамбәр колларны азат итәргә өндәгән һәм үзе моңа үрнәк күрсәткән, ләкин ул коллык институтын бөтенләй сызып та ташламаган. Шәригать коллыкны, аерым алганда, әсирлек нәтиҗәсендәге коллыкны, хәзергәчә таный. Хәнифи мәзһәб әсиргә үлем җәзасы бирүне яки аны колга әйләндерүне күздә тота, ул хәтта, башка мәзһәбләрдән аермалы буларак, колны сатып алу мөмкинлеген тикшерми дә. Шуңа күрә кеше хокуклары турындагы хәдисләрне бүгенге вазгыятькә күчерергә ярамый.

Кеше хокукларын заманча шәрехләү АКШ Конституциясенә беренче ун төзәтмә керткән вакыттан башлана, ләкин биредә дә әлеге төшенчәнең эволюциясенә игътибар итәргә кирәк. Бу төзәтмәләрнең мәгънәсе федерациянең штат гражданнары мәнфәгатьләренә кул сузуыннан саклаудан гыйбарәт. Бары тик Икенче бөтендөнья сугышыннан соң гына кеше хокуклары шәхси хокуклар буларак аңлатыла башлый, һәм, әкренләп, аларның бүгенге мәгънәсе ныгытыла. Бу урында нокта куярга да мөмкин булыр иде, ләкин кеше хокуклары темасын тикшергәндә Русия үзенчәлекләрен күрсәтмәсәк, фикер төгәлләнми калачак. «Милләтчеләр» дип аталучылар кеше хокукларының төп өлеше итеп этник мәнфәгатьләрне яклауны санап, алар турында кайгырткан мәлдә, Русиянең урыс телле халкы кеше хокукларын гражданлык хокуклары дип аңлый. Шул рәвешле, пәйгамбәр әйткән кеше хокуклары һәм безнең җәмгыятьтәге кеше хокуклары — икесе ике төрле күренеш. Бу очракларның һәммәсе өчен аерым терминнар куллану дөресрәк булыр иде, ләкин андый терминнар әлегә эшләнмәгән.

Коръәннең асылына шул чордагы яшәеш шартларын һәм шул чор культурасы вәкилләренең менталитетын яхшы белгән хәлдә генә төшенергә мөмкин. Аны, пәйгамбәр XXI гасырда яшәгәндәй, сүзгә-сүз укырга, безнең җәмгыятькә VII гасырда килеп чыккан терминнарны көчләп тагарга ярамый.

> *«Әнә шулай һәрнәрсәне бәян итүче Коръәнне гарәп телендә иңдердек вә ул Коръәндә газап белән куркытуны күп кабатладык, кешеләр газаптан куркып гөнаһтан саклансыннар өчен яки әүвәлге каумнәрнең хәлләрен бәян итүче көчле вәгазь булсын өчен»* [20:113].

Тел үз заманының һәм үзен кулланган халыкның тирәлеге контекстында гына яши.

Коръән гарәпләргә «ап-ачык гарәп телендә» билгеле бер вакыйгалар турында иңдерелгән. Аларны дингә ышандыру шулай җиңелрәк булган. Мәсәлән, Изге китапта әйтелгән: *«Әбү Ләһәбнең ике кулы корысын һәм һәлак булсын!»* [111:1]. Сүз Мөхәммәд пәйгамбәрнең аңа зарар тидерергә тырышкан абзасы турында бара. Бу очракта анык мәсьәлә һәм аның чишелешен табу ихтыяҗы булган. Бүген исә әлеге аять Пәйгамбәр тормышының бер күренешен искә төшерү булып кына тора, ул хәзерге заманда кулланыла алмый, өстәвенә Әбү Ләһәбнең кулларына барыбер зыян килмәгән.

Теге яки бу хәрби экспедицияләргә кагылышлы рәвештә иңдерелгән сүрәләр бар. «Тәүбә» сүрәсенең 25 нче аятендә әйтелгән: *«Аллаһ, сезгә күп урында вә хөнәен көнендә ярдәм бирде, ул хөнәен көнендә сезне үзе-*

*гезнең күплегегез гаҗәпләндерде, ягъни без мөшрикләргә караганда бик күпбез, җиңелмәбез, — дидегез, хәлбуки күплегегез сезгә һич файда бирмәде, киң җир сезгә тар булды, соңра артка таба качтыгыз»*. Бу аятьтә күпсанлы тарихи вакыйгаларның берсе турында әйтелгән. Коръәндә гарәп кабиләләренең яшәешенә кагылышлы сюжетлар күп.

> *«Әгәр без Коръәнне гарәп теленнән башка телдә кылсак иде, әлбәттә, әйтерләр иде: «Ни булыр иде бу Коръәннең аятьләре без аңлый торган гарәп телендә бәян ителгән булса, пәйгамбәр үзе гарәп, китабы башка телдә, дип, янә инкурләрен арттырыр иделәр»* [41:44].

Коръәннең көче аның төгәллегендә, ул корәешләрне һәм башка кабиләләрне хак юлга бастыру мөмкинлеге биргән, ләкин шул ук вакытта шушы төгәллек үзе үк безнең заман өчен кыенлыклар тудыра. Сорау туа: Коръәндә нәрсә билгеле бер вазгыять өчен әйтелә, ә нәрсә мәңгелек өчен иңдерелеп универсаль үзенчәлеккә ия? Бар нәрсәне дә бүгенге көнгә күчерергә ярамый лабаса. VII гасыр гарәпләренең тормышы безнең өчен үрнәк була алмый. Бу, әлбәттә, бик әһәмиятле һәм гыйбрәтле тарих, ләкин барыбер тарих кына.

Мин Татарстанда яшим һәм минем урта гасыр гарәбенә охшыйсым килми, мин — татар һәм татар булып каласым килә. Минем өчен үз халкымның тарихы мөһимрәк, татарларның Евразия язмышына йогынтысы гарәпләрнең Көнчыгыш тарихына йогынтысыннан һич ким түгел. Минем өчен шулай ук урыслар тарихын һәм халкымның төп өлеше яшәгән Русиянең тулаем тарихын белү дә бик мөһим.

> *«Ул пәйгамбәрләрне могҗизалар вә китап белән җибәрдек. Ий Мөхәммәд г-м, Без сиңа Коръән иңдердек, кешеләр өчен хаслап иңдерелгән шәригать хөкемнәрен өйрәтмәклегең өчен, шаять, ишетеп, фикерләп карарлар вә аңлап кабул итәрләр!»* [16:44].

Мәккә чорында Коръән аятьләре барлык кешегә дә юнәлтелә. Әйтелгән: *«Ий кешеләр, Без сезләрне ир вә хатын итеп халык кылдык, вә сездән тармаклар, вә кабиләләр кылдык, бер-берегезне аерып танымаклыгыгыз өчен»* [49:13]. Анда ир-ат һәм хатын-кыз хокуклары арасында аерма юк, кешеләрне ислам юлына кертүдә көч куллану тыела, башка дин кешеләренә карата түземле мөнәсәбәт ачык чагыла.

Мәдинә чорында исә аятьләр күбрәк VII гасыр гарәпләренә юнәлтелә һәм мәҗүсиләргә карата мондый күрсәтмәләр бирелә: *«Кяферләр сезгә каршы сугыш башласалар, кайда очратсагыз шунда үтерегез һәм алар сезне чыгарган кеби, аларны өйләреннән чыгарыгыз»* [2:191]. Хатын-кызларны ир-атлар белән хокук ягыннан тигезсез итүче аятьләр барлыкка килә. Әйтелгән: *«Аллаһ мәхлукларны кайберләрен кайберләреннән артык кылу белән, ирләр акылда, куәттә хатыннардан өстен булды һәм малларын хатыннарга инфак кылу белән дә ирләрнең дәрәҗәсе өстендер»* [4:34]. Яки: *«Аллаһ балаларыгыз хакында булган мирасны бәян итәдер, үзегез үлеп, балаларыгыз калганда, ир балага хатыннарга биргәннең ике өлеше бирелер»* [4:11]. Әлбәттә, моны аңлатучылар табыла һәм моны гадел принцип дип атыйлар, чөнки тормышта ирләр җилкәсенә зуррак җаваплылык салына, ләкин тигезсезлек барыбер тигезсезлек инде ул.

Мәккә һәм Мәдинә чорлары аятьләре арасында каршылыклар ачык күренә һәм аларны бер-берсенә яраштыру мөмкин түгел — алар бер-берсен инкарь итә. Шуңа күрә мөселман хокукы белгечләре Мәккә чоры аятьләрен, элегрәк иңдерелү сәбәпле, гамәлдән чыккан дип саныйлар. Ләкин вәхи ителү вакыты — бер аятьләрне тәэсир көче буенча икенчеләреннән өстенрәк дип санау билгесе түгел. Әгәр дә алар чынбарлыкта гамәлдән чыгарылган булса, имеш, «гамәлдән чыгарылган», дип аталучы элеге аятьләрне Пәйгамбәр үзе Коръән текстына кертмәс иде. Мәгълүм ки, Коръәнне укытучы дүрт төп белгеч: Абдулла бин Масуд, Сәлим Мәүла Аби Худхәйфә, Муаз бин Җабал һәм Гобәйя ибн Кааб турыдан-туры аның күзәтчелегендә хәзерләнә. Аның бу мәсьәләдә ни дәрәҗәдә вакчыл булганлыгын бары тик бер генә сүзнең әйтелеше турындагы вакыйга ачык күрсәтеп тора. Гомәр бервакыт Мөхәммәд пәйгамбәргә Абдулла бер фигыльне дөрес әйтми дип зарланган. Шуннан соң Мөхәммәт, аларның икесен дә тыңлап, авазның дөрес әйтелешен раслый. Пәйгамбәр исән чакта ук Коръәнне яттан белүчеләр күп булган. Бервакыт Пәйгамбәргә Әбү Мусаның үз йортында кешеләрне Коръән укырга өйрәтүе хакында хәбәр иткәннәр. Пәйгамбәр үзен шул йортның Мусаның тыңлап була торган бер бүлмәсенә яшерен рәвештә алып керүләрен үтенгән. Һәм ул Коръән укуларын тыңлаганнан соң канәгать калган. Мөхәммәд пәйгамбәр Коръән текстының төгәл сакланышын игътибар белән күзәтеп торган. Әйткәнемчә, әгәр дә ул кайбер аятьләрне гамәлдән чыккан дип санаса, аларны Коръән текстына кертмәс иде. Инде Пәйгамбәр үзе аятьләрне гамәлдән чыгару вазифасын үз өстенә алмаган икән, ни өчен нindидер башка берәүнең моңа хакы булырга тиеш?

> *«Тиздән укырбыз сиңа Коръән аятьләрен һәм син онытмассың. Мәгәр, Аллаһ теләгәнне генә онтырсың, әлбәттә, Ул яшерен эшләнгән эшләрне дә, һәм әшкәрә эшләнгән эшләрне дә беләдер»* [87:6—7].

Бүген дә Мәккә чоры аятьләрен безнең заман өчен әһәмияте аз дип шул ук рәвешле гамәлдән чыгару ысулын кулланырга мөмкин. Габдуллаһи Әхмәт ән-Наим болай дип яза: «Коръәнне аңлатуга эволюцион караш — Коръәннең элегрәк гамәлдән чыгарылган текстларын хәзер кулланырга мөмкин булырлык итеп һәм, шуңа ярашлы рәвештә, шәригатьтә элегрәк кулланылган текстларны хәзер гамәлдән чыгару мөмкин булырлык итеп кире якка юнәлдерелгән нәсех (яки гамәлдән чыгару процессы) кенә ул». Чынлыкта исә аятьләрнең һәр төренең (Мәккә чоры, Мәдинә чоры аятьләре) үз кулланылыш даирәсе һәм үз өммәте булган: принципларның берләре барлык халыклар өчен һәм мәңгегә иңдерелгән, ә икенчеләре — күбрәк урта гасырлар башында яшәгән гарәпләр өчен иңдерелгән. Коръәндә бер генә нәрсә дә гамәлдән чыгарылмаган һәм чыгарылмый да, әмма алар юнәлдерелгән бергәлекләр төрле.

Мәдинә җәмгыяте беренче ислам дәүләте буларак барлыкка килгән. Яңа туган бала шикелле, ул зурлар ризыгын ашый алмый, ана сөте имә; тәүге мөселманнар да шулай ук: мәңгелек нәрсәне кабул итә алыр өчен үсәргә тиеш булганнар. Алардан шуннан да артыгракны таләп итеп булмаган. Мәдинә чоры аятьләре үз заманы өчен хакыйкать булганнар, алар ислам барлыкка килгән җәмгыятьнең теленә, уй-фикерләренә, хиссиятенә тыгыз бәйләнгәннәр, алар үзләренең тарихи чорына тулысынча тәңгәл киләләр. Һәм зур үскән бала сабый телен онытырга тиеш булган кебек, ислам да, ныгып, Мәккә теленә күчәргә тиеш булган. Вакыты җиткәч, «Китаплар анасы»ннан алынган һәм бөтен кешелеккә җибәрелгән Мәккә чоры аятьләре үз көченә керә.

> *«Аллаһ теләгән нәрсәсен бетерер һәм теләгән нәрсәсен бар кылыр, вә китаплар анасы Ләүхелмәхфүз — Аллаһы хозурындадыр»* [13:39].

«Китаплар анасы»н аңлату, хакыйкатьне конкрет халыкларга һәммәсенең ана телендә җиткерү өчен пәйгамбәрләр җибәрелгән. Мөхәммәд пәйгамбәр әйткән: «Безгә, пәйгамбәрләргә, кешеләр белән алар безне аңларлык дәрәҗәдә сөйләшергә кушылды». Коръәнне гамәлдәге менталитетка һәм гореф-гадәтләргә яраштырып аңлатырга кирәк була.

Аятьләрнең берләрен икенчеләре белән гамәлдән чыгарылган дип санау — Аллаһы Тәгаләнең ихтыярын түбәнсетү яки аның вәхиләрен ялгыш дип санау. Әйтелгән: *«Әгәр кайбер аятьләрнең хөкемнәрен үзгәртсәк яки оныттырсак, ул аятьләргә охшашлы аятьләрне яки яхшыракны бирербез»* [2:106]. Беренче карашка сүз Коръәннең кайбер аятьләрен гамәлдән чыгару мөмкинлеге турында бара шикелле тоела. Ләкин алдагы аятьләргә карасак [102—105], фикер тулысынча ачыла. Анда сүз христианнар, яһүдләр, күп аллаларга табынучылар турында бара, аларга да «китап җибәрелгән». Аннан соң килгән 106 нчы аятьтә инде сүз «аятьләрнең хөкемнәрен үзгәртү» турында бара. Димәк, «гамәлдән чыгару» принцибы Коръәнгә түгел, китапка карый.

Аллаһы Тәгалә Җиргә күп пәйгамбәрләр җибәргән, ләкин алар Алла сүзен тулысынча җиткерә алмаганнар. Аларның дәлилләрендә ялгышлыклар һәм ачыкланып җитмәгән урыннар барлыкка килгән. Әйтелгән: *«Синнән элек тә пәйгамбәр вә рәсүл җибәрмәдек, мәгәр җибәргән рәсүл вә пәйгамбәр бер нәрсәне сөеп теләсә, шайтан аның теләгән нәрсәсенә вәвәсәсенә салыр иде, шайтан салган нәрсәне Аллаһ бетерер, вә аларга биргән аятьләрен мәхкәм таза кылыр иде, бит Аллаһ белеп һәм хикмәт белән эш кылучы»* [22:52]. «Китаплар анасы» буенча, Коръәнгә элеккеге язмаларның хаталарын бетерү вазифасы йөкләтелгән, әмма аның үзендә бернәрсә дә гамәлдән чыгарылмый, чөнки ул Ходайдан иңдерелгән вәхи.

Нәсех ысулы урынына иҗтиһад кулланылырга тиеш, ул Мәдинә җәмгыятенә юнәлдерелгән аерым принциплардан, әкренләп барлык кешелек өчен җибәрелгән нормаларга күчәргә мөмкинлек бирә.

Кайчандыр кешелек бердәм Ибраһим өммәтен тәшкил иткән. Аннан соң ул бүленгән. Төрле диннәр һәм берләшмәләр барлыкка килгән, алар бер-берсе белән дошманлашканнар да, хезмәттәшлек тә иткәннәр, кайвакыт берлекләр дә төзегәннәр. Империяләр барлыкка килгән һәм таркалган. Вакытлар узу белән өммәт төшенчәсе үзе дә үзгәргән. Бүген бөтен кешелек бердәм бергәлек булып тора.

Иҗтиһад, ислам нормаларын Коръән рухыннан чыгып заманча шәрехләүне тәкъдим итеп, җәмгыятьнең эволюциясен исәпкә алырга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, җиһад, кяферләргә каршы сугыш буларак, урта гасырларда аңлаешлы мәгънәгә ия булган, чөнки ул чор өчен көч сәясәте — гадәти күренеш. Ләкин Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, сугыш алып бару ысуллары һәм кешелек яшәешенә янаган куркыныч үзара чагыштырырлык дәрәҗәгә җиткәч, шартнамә мөнәсәбәтләре һәм халыкара хокук элеккеге көч куллану принцибыннан өстенрәк булып чыктылар.

Пәйгамбәр көч кулланыла торган кече җиһадны, исламны Коръән ярдәмендә таратуны күздә тоткан бөек җиһадтан аерып караган. Әйтелгән*: «Инде син имансыз динсезләргә итагать итмә, аларга иярмә һәм аларга хезмәт итмә, бәлки ялган иман, ялган дингә вә имансызлыкка, динсезлеккә каршы Коръән белән көрәшү юлын ач, зур көрәшү белән көрәш!»* [25:52]. Кече җиһад мөселманнарга башка дәүләтләр тарафыннан куркыныч янаган вакытта, урта гасырлар чорына хас рәвештә, ислам тарафыннан яңа биләмәләр яулап алынганда кирәк булган. Бүген сугыш һәм тынычлык мәсьәләләренең регламенты башкача билгеләнә. Шуңа күрә җиһадны бүген турыдан-туры мәгънәсендә, ягъни «тырышлык», матди дөньяга каршы, рухи башлангыч өчен «көрәш», үз-үзеңә ышанмаучылык белән «көрәш» дип аңларга кирәк. Бу мәгънә Аллаһ тарафыннан барлык заманнар өчен бирелгән. Кече җиһад, әгәр дә ул гадел булса, үз-үзеңне яклау максатында басып алучылар һәм тираннарга каршы көрәшү өчен игълан ителә, бу Коръән текстына гына түгел, халыкара хокук кысаларына да туры килә.

Аятьләрне шәрехләгәндәге мондый аерымлыклар бүгенге көндә бигрәк тә мөһим. Ваһһабичылык башка диннәр, хәтта исламдагы башка агымнарга да каршы көрәшкә юнәлдерелә. Исламның «сафлыгына» өндәп, чынлыкта ул ханбали мәзһәбнең ахыр чиктәге чагылышына — рациональлекне тулысынча инкарь итүгә ияреп бара. Имеш, Коръәнне аңлау мөмкин түгел, аңа бары тик ышанырга гына кирәк. Моның белән ул бернинди дә яңа күренешләрне танымый торган традициячелекне яклый.

> *«Пәйгамбәр килгәнче дөньядагы кешеләр бер генә төрле иде, ягъни бар да мөшрик иделәр, Мөхәммәд г-м килгәч, берсе мөэмин, берсе мөшрик — икегә бүленделәр»* [10:19].

Ике бөтендөнья сугышыннан соң кешелек өченчесе барлыкка килүгә каршы механизмнар булдырды. Бүген мөселман өммәте эчендә иҗмагъ (консенсус) турында сүз куертуның мәгънәсе юк. Барлык мөселман илләре Мисыр өммәте, Иордания өммәте һәм башкалар кебек мөстәкыйль халыклар булып яшиләр. Кешелек — бердәм бергәлек һәм куркынычсызлыкны, тынычлыкны, тотрыклылыкны барыннан да югары бәяли.

Иҗтиһадның тагын бер үрнәге. Әйтелгән: *«Аллаһ аларның күңелләрендәге яхшы ниятләрен белде, аларга күңел тынычлыгын бирде һәм тиздән Мәккә фәтех ителәчәк, мөселманнар кулына үтәчәк, дип, аларны шатландырды. Дәхи күп табыш малларын бирде, алар ул табыш малларын Хәйбәрдән алырлар, Аллаһ җиңүче, вә эшне белеп кылучы булды. Аллаһ сезгә күп табыш маллары вәгъдә кылды, алырсыз ул табышларны Хәйбәрдән, һәм ашыктырды сезгә ул табышны, вә дошман булган кешеләрнең кулларын сездән тыйды, ягъни табыш малы алудан сезне туктата алмаслар. Аллаһ бу табыш малларын бирде, пәйгамбәрнең хаклыгына мөэминнәргә дәлил булсын өчен һәм сез мөселманнарны туры юлга күндермәк өчен»* [48:18—20]. Үткән заманнарда табыш кешеләрне хәрәкәткә китерүче сәбәп булган. Бүген исә табыш бүлешү кыргыйлык булыр иде, гәрчә Коръәндә бу мәсьәләләр ныклап каралган булса да. Кешелек гасырлар буе сугышлар алып барган, сугышлар вакытында табышлар кулга төшергән, ләкин бу чорлар инде узган. «Табыш» сүрәсендә әйтелгән: *«Вә белегез сугышта ганимәт алган нәрсәгезнең биштән берсе Аллаһыга вә Аның рәсүленәдер, калган дүрт өлешен рәсүлгә якынлыгы булган кешеләргә, ятимнәргә, мескеннәргә вә мөсафирларга бирелер, әгәр Аллаһыга һәм бәдер сугышында хак белән батыйль аерылган көндә иңдерелгән аятьләргә ышансагыз, ул көндә мөшрикләр гаскәре белән мөэминнәр гаскәре каршы юлыктылар»* [8:41]. Табыш бүлешү бүгенге көндә диңгездәге «диндар» юлбасарлар өчен генә актуаль булуы мөмкин.

Табыш темасын йомшартып та, ничек тә булса боргалап та булмый. Бу тема үткән заманда калырга тиеш. «Шәригать рөхсәт иткән бар нәрсә һәрвакыт файда китерә, — дип яза Йосыф әл-Кардави, — шәригать тыйган нәрсәләр исә һәрвакыт зыян китерә». Аятьләрнең кайсы өммәткә җибәрелгәнен аермасак, коллыкны һәм табышны бүген дә файдалы нәрсәләр дип санарга туры килә, ә бу цивилизацияле җәмгыять нормаларына каршы килә.

Талау, кеше урлау һәм башка күренешләрне аклау өчен бернинди дә мөмкинлек калмаска тиеш, гәрчә боларны дин белгечләре бидгать дип исәпләсәләр дә. Ахыр чиктә, җәһәннәмгә, шәригать буенча «гадел» исәпләнгән табыш бүлешүне аклаган өчен түгел, бидгать өчен керүең яхшырак. Чөнки андый мантыйкка иярсәң, теләсә нинди сәясәтне аклауга кадәр барып җитәргә мөмкин. Әйтелгән: *«Динсезлек коткысына бирелү сугышта кеше үтерүгә караганда яманрак»* [2:191]. Коръәнне гомуми контексттан чыгарып һәм кемгә әйтелгәнен исәпкә алмаган очракта, мондый гыйбарәләрне теләсә ничек шәрехләргә мөмкин.

Мөхәммәд пәйгамбәр заманында кешеләрне күпләп үтерү коралы булмаган. Ул заманда кяферләр белән көрәшкә өндәү башка мәгънәгә ия булган һәм башка ысулларны күздә тоткан. Бүгенге көндә мөселманнарга Мәккә чорында иңдерелгән, гомумтеләктәшлек дигән мәңгелек идеягә таянырга кирәк, чөнки игелеккә омтылучы кешелек — Аллаһы Тәгаләнең бер чагылышы ул.

Әлбәттә, пәйгамбәрнең тормышы гыйбрәтле, Х гасыр ислам илләренең тәҗрибәсе дә файдасыз түгел, ләкин бүген коллык та, баскынчылык та, табыш бүлешү хаҗәте дә юк. Шәригать буенча, кеше үтергән

адәм бер колны азат итәргә тиешле. Әйтелгән: *«Бер мөэмин хаталык белән бер мөэминне үтерсә, кәффарәте — мөэмин булган бер колны азат итүдер һәм үтерелгән мөэминнең варисларына кан хакын түләүдер...»* [4:92]. Шәригатьтә язылганны төгәл үтәү өчен яңадан коллык кертергә кирәк түгелдер бит? Өстәвенә пәйгамбәр үзе үк колларны азат итүдә үрнәк күрсәткән һәм ул күңеленнән коллыкка каршы булган, ул коллык институты белән карашы буенча түгел, мәҗбүрилек сәбәпле исәпләшкән. Пәйгамбәр заманында кәгазь акчалар, кеше әгъзаларын күчереп утырту, атом реакторлары булмаган һәм космоска да очмаганнар. Мөхәммәднең, һичшиксез, клонлаштыру турында да, Берләшкән Милләтләр Оешмасы эшчәнлеге турында да үз фикере булыр иде, чөнки заманалар нык үзгәрде.

X гасырда мөселман дин белгечлегендә «иҗтиһад капкалары ябылу» дип аталган күренеш барлыкка килгән. Тәнкыйди, аналитик фикерләү тыелган. Барлык кирәк нәрсәләр дин белгечләре тарафыннан тикшерелеп беткән инде, дип саналган. Шул вакыттан бирле мөселманнар X — XIII гасырлар нормалары белән дүрт мәзһәб кысаларында яшиләр. Мәккә чорының уңайсыз аятьләре күрсәтмәләрен үтәмәс өчен, нәсех төшенчәсе кертелгән. Мәзһәбләр — Коръәннең һәм сөннәтнең кешеләр тарафыннан шәрехләнүе нәтиҗәсе. Бу Ходайдан иңгән вәхи түгел, ләкин алар хәзергәчә сакланып килә.

Мәзһәбләргә нигез салучылар үзләре үк әһәмияте ягыннан шәригатьнең икенче чыганагы булган хәдисләрнең төгәл исәбе турында да төрле фикердә булганнар. Ибн Халдун сүзләренә караганда, имам Әбү Хәнифә бары тик унҗиде хәдис кенә кулланган, Мәлик исә өч йөз хәдис санап чыгарган, күренекле Әбү Абдуллаһ Мөхәммәт ибн Исмәгыйль әл-Бохари — хәдисләрнең иң мәшһүр җыентыгын төзегән кеше — хәдисләр санын җиде меңгә җиткергән, ә имам Әхмәт ибн Ханбал 50 мең хәдис бар дип санаган. Ул заманда иҗтиһад хәтта шәригатьнең иң мөһим чыганагы булган Сөннәткә карата да кулланылган, ә бүген исә дин белгечләре аны икенчел дәрәҗәдәге мәсьәләләр белән чиклиләр.

> *«Бәдәви гарәпләре, кяферлектә вә монафикълыкта тагы да куәтлерәкләр һәм алар Аллаһ үзенең рәсүленә иңдергән хөкемнәрне белмәскә бик лаеклыдыр, чөнки алар кырда яшиләр»* [9:97].

Аллаһы Тәгалә могҗизаларының берсе — һәркайсы үз телендә сөйләшә торган күпсанлы халыклар. Әйтелгән: *«Җир вә күкләрнең төзелеше, вә телләрегез, вә төсләрегез төрлечә булуы Аллаһының галәмәтләреннәндер, әлбәттә, Аллаһының бу эшләрендә белем ияләре өчен дәлилләр бардыр»* [30:22]. Аллаһы Тәгалә, теләсә, барлык кешеләрне дә гарәп телендә сөйләшүче бер халык итеп яратыр иде. Ләкин Ул алай эшләмәгән. Һәрбер халыкның үз тормышы бар. Ходай өчен башкалар арасыннан сайлап алынган коткаручы (мессия) халык яисә мөртәт халык юк. Яһүдләр һәм гарәпләр Аллаһтан вәхи иңдерелгән күп халыкларның кайберләре генә.

Аллаһы Тәгалә теләсә нинди телне аңлый. Адәм баласы Ходай белән үз җанына якын ана телендә сөйләшергә тиеш. Күңел түрендәге уй-теләкләреңне чит телдә аңлатып бирү мөмкин хәлмени?! Аллаһы Тәгаләгә тылмач кирәкми, ул бер генә халыкка да, бер генә телгә дә өстенлек бирми. *«Ул — Аллаһ, күкрәк эчендәге нәрсәләрне белүчедер»* [42:24].

> *«Әгәр Раббың теләсә иде, бөтен кешеләрне бер генә диндә кылыр иде»* [11:118].

Бер генә халык та мәңгелек түгел. *«Һәрбер өммәтнең билгеләнгән әҗәле бар, әгәр аларга әҗәлләре килсә, бер сәгать иртә килмәс һәм бер сәгатькә кичекмәс»* [7:34]. Гарәпләр кайчандыр иң алдынгы халыкларның берсе булганнар, әмма алар заманы узган. Кайчандыр татарлар да бөтен Евразия белән идарә иткәннәр дә бит...

Мөселман цивилизациясе аерым халыкларны үз эченә йотмый, гамәлдән чыгармый. Татарлар язмыш ихтыяры белән исламның православие белән чолгап алынган төньяк терәге булып чыкканнар. Русиядә мөселманнарның үз традицияләре барлыкка килгән.

Русиядә ислам һәрвакыт икенче урындагы дин булган. Ләкин соңгы елларда протестантлык оешмалары мөселман оешмаларын сан буенча узып китте. Алар ыргылып үсеп киттеләр. Татар яшьләре дә, урыс яшьләре дә яңа дингә тартылдылар. Урыслар тумыштан ук православие динендә, татарлар — мөселманнар дигән тотрыклы стереотип күз алдында юкка чыкты. Бу күренешне аңлату авыр түгел. Протестантлар чиркәү-славян телендә яки урта гасыр гарәп телендә сөйләшми, алар кешегә балачактан якын ана телендә аралашалар. Протестантлар Библияне заманча аңлаталар, ул борынгы һәм иске китап булып тоелмый. Алар кешеләргә тормышларындагы конкрет мәсьәләләрне хәл итәргә булышалар.

Сәид Мөхәммәт Нәкыйб әл-Әттас «мөселман теле» дигән төшенчәне керткән, аның фикеренчә, бу — «ислам динен тотучы халыкларның телләренә мөселман терминологиясенең төп сүзлеген кертү. Шул рәвешле һәрбер мөселман халкының теле барлык мөселманнар өчен дә үз булган сүзләрнең төркеме аша

башка мөселман халыкларының телләренә бәйләнгән булып чыга. Менә шул сәбәпле мөселман халыкларының барысының да телләрен, нигездә, мөселман телләре дигән бер төркемгә кертеп булыр иде». Чынлап та, татар теле мөселман терминологиясен шактый тулы чагылдыручы гарәп сүзләре белән тулган һәм бу хәл дин тотучыларның киң даирәсенә гарәп телен белүне артык нәрсәгә әверелдерә. Бу нисбәттән, Көнбатыш традицияләренә таянучы урыс теле шундый ук мөмкинлекләргә ия түгел. Сәид Мөхәммәт Нәкыйб әл-Әттас тезисы — исламга лингвистика ягыннан национализация ясау файдасына бик җитди дәлил. XXI гасырда бу котылгысыз була бара.

> *«Аллаһ ризалыгын өстәп көндезләрен вә кичләрен Раббыларына гыйбадәт кылган зәгыйфь яки фәкыйрь мөэминнәрне яныңнан кума! Ул кяферләрнең гамәленнән һичнәрсәне хисап итмәк сиңа тиеш түгел һәм синең гамәлеңнән һичнәрсәне хисап итмәк аларга тиеш түгел. Дошманнар сүзенә карап фәкыйрьләрне яныңнан кума! Әгәр кусаң, залимнәрдән булырсың»* [6:52].

Хакыйкатькә берәү дә дәгъва кыла алмый, хакыйкатькә бары тик Аллаһы Тәгаләнең генә хокукы бар. «Әйт: *«Хак юлга фәкать Аллаһы Тәгалә үзе генә күндерә!»* [10:35]. Без үз фикерләребезне бары тик әйтә генә алабыз. Ихтимал, минем фикерләр исламны мөстәкыйль рәвештә аңларга тырышучылар, үз юлын эзләүчеләр арасында яңгыраш табар — без бит бер буын, бер дин һәм бер заман — Русия өчен югалган гасыр кешеләре.

Минем өчен тәрҗемәнең яки аерым аятьләрне шәрехләүнең нечкәлегенә төшенү, Аллаһы Тәгалә сыйфатларының санын, теге яки бу гарәп терминнарының дөрес әйтелешен белүне ачыклау зарурлыгы юк — бу эшләр барысы да дин белгечләре һәм имамнар карамагында калсын. Минем мәхәлләм дә, мәчетем дә юк, мин вәгазьче дә түгелмен. Миңа үз тарафдарларымның санын арттыру кирәкми, мине сәдака да кызыксындырмый. Миңа исламның теләсә нинди телдә дә бертөрле шәрехләнә торган төп принципларын белергә кирәк: ир-ат һәм хатын-кыз — тигезме, түгелме; бүгенге көндә имамнарның вазифалары нинди; кешелек — өммәтме яки бергәлек мөселманнар арасында һәм саф ислам илләрендә генә була аламы? Һәм, мөгаен, иң мөһиме: ислам минем халкыма алдынгы милләт булырга ничек ярдәм итә ала? Чөнки бүген халыкны ниндидер мөселман резервациясендәге экзотик этнос сыйфатында саклап калу бурычы тормый, максат башка — конкурентлыкка сәләтле булу. Ислам прогресс юлын күрсәтергә тиеш. Минем өчен ислам һәм прогресс сүзләре — синонимнар. Әмма моңа җавап итеп мин укыйм: «Аларның иң куркынычлары — прогресс тарафдарлары».

Татар яшьләре замана университетларына омтыла, кайберләре, чит телләрдән инглиз теленә өстенлек биреп, Европа уку йортларына юнәлә. Инглиз теле эшкуарлыкта, сәясәттә, фәндә ярдәм итә, инглиз теле аша без иң яңа идеяләрне, заманча технологияләрне, соңгы ачышларны белә алабыз. Шәһәр (авыл) татарлары арасында балалары гарәп телен белүне теләүчеләр 13% (25%), төрек телен — 10% (19%), Көнчыгыш Европа телләрен — 74% (33%). Татар яшьләре арасында Көнчыгыш Европа телләрен өйрәнергә теләүчеләр саны ата-аналары арасындагыдан күбрәк. Тенденция шундый: гарәп теле ритуаль яки саф һөнәри тел булып кала, ә чит телләр арасында «киң массалар» теле булып инглиз теле санала башлады. Бу — заман таләбе, чөнки гарәп теле безнең җәмгыятькә артта калганлык төсмере кертә, ә Көнчыгыш Европа телләре исә безгә алгы сызыкка чыгарга мөмкинлек бирә. Әгәр дә без Европадан өйрәнмәсәк, «КамАЗ» «Вольво»га һәм «Мерседес»ка оттырачак, Казан вертолетлары «Еврокоптер»ныкыннан начаррак булачак, безнең пассажир самолетлары «Боинг»ка конкуренция ясый алмаячаклар. Имамнар республиканың икътисады һәм культурасын үстерүгә катнашырга тиешләр! Алар биш вакыт намаз турында гына искә төшерергә түгел, безнең тормышны яхшырта торган икътисади һәм социаль проектлар тәкъдим итәргә, мөселман дөньясындагы базарларны яулап алуга ярдәм итәргә тиешләр. Русия ислам университеты, дин белгечлегеннән тыш, үз алдына яңа икътисади теорияләргә өйрәтүне иң мөһим бурыч итеп куярга, Татарстанның югары технологияле төбәк буларак үсешендә үз юлларын табарга тиеш. Әбү Хәнифә әйткән: «Үз белемегезне гамәлдә кулланыгыз, чөнки гамәлсез белем — җансыз гәүдә».

Муса Бигиев «Ходай рәхмәтенең абсолютлыгы» (Рәхмәт Илаһия Борһанлары) теориясенең нигезләрен чыгара башлагач, дуслары аңа бераз гына дипломат булырга, имамнарның ачуын китермәскә киңәш итәләр. «Син бернинди файдасыз проблеманы вакытсыз һәм урынсыз күтәрдең һәм давыл кузгаттың», — диләр аңа. Муса Бигиев исә: «Мин, әлбәттә, дусларыма үгет-нәсихәтләре өчен рәхмәтлемен. Ләкин үземнең фәнни эзләнүләремдә мин, имеш-мимешләрдән куркып яки үземнең ашар икмәгем хакына үз абруемны корбан итә алмыйм. Әгәр дә берәр хакыйкать бөтен дәлилләре белән минем йөрәктә тамыр җәя икән, кешеләр кабул итә алмас дип, мин аны яшереп кала алмыйм», — дип җавап биргән.

Кешегә хөкем кылмагыз һәм хурламагыз!

*«Ий мөшрикләр, кояш чыга торган якка һәм кояш бата торган якка юнәлеп табынуларыгыз Аллаһы хозурында изгелек түгел. Ләкин берәү Аллаһыга, ахирәт көненә, фәрештәләргә, китапларга һәм пәйгамбәрләргә иман китереп, үзенә кадерле малыннан мохтаҗ булган якын кардәшләренә, ятимнәргә, мескеннәргә, мөсафирларга, мохтаҗлыктан ярдәм сораучыларга һәм колларны азат итү юлына сәдакалар бирсә, шулай ук зәкят, гошер сәдакаларын бирсә, намазларын вакытында үтәсә, янә Аллаһыга биргән гаһеден, кешеләргә биргән вәгъдәсен үтәсә, янә ярлы вакытта нинди дә булса бәла-каза ирешкәндә, ачлык яки сугыш килгәндә сабыр итсә, Аллаһыга чыдамлылык күрсәтсә, әнә шул эшләр изгелекләр»* [2:177].

Мәккәдә чагында Мөхәммәд пәйгамбәр Кәгъбәгә карап дога кылган, Мәдинәгә качканнан соң, ул догаларны Иерусалим ягына борылып укыган. Моңа яһүдләр бик шатланганнар. Ләкин унҗиде айдан соң ул яңадан Кәгъбә тарафына борылган. Күпләр аның болай икеләнүен өнәмәгән: мөселманнарның кыйбласы кайда соң? Шул вакытта яңа аять барлыкка килгән.

*«Кояш чыгыш тарафы да, кояш батыш тарафы да Аллаһы Тәгаләнекедер. Аллаһы үзе теләгән бәндәсен туры юлга күндерер»* [2:142].

Дога кылганда кая таба юнәлеп басуны билгеләү Ходай ихтыярында. Мөселманнар шуннан бирле Кәгъбәгә карап дога кылалар. Ихтимал, бу мөселманнарны яһүдләрдән һәм христианнардан аеру өчен иңдерелгәндер, әйтелгән бит: «*Һәр милләтнең үз кыйбласы бар, һәрберсе үз кыйбласына юнәлер»* [2:148]. Ходай Тәгалә һәрбер халыкка үз кыйбласын билгеләгән, ләкин ул үзе үк аларны берләштерәчәк һәм Ходай рәхмәте барсына да җитәчәк.

Татар телендә кыйбла төшенчәсе дога кылу ягы гына түгел, аның мәгънәсе тирәнрәк. Тормыш принципларың нинди? Синең өчен нәрсә изге? Иманың бармы? «Кыйбла» сүзенең асылы менә шунда. Һәр телдә сүзләрнең үз мәгънәләре бар, аларда милли тарих туплана...

Вакытлар уза һәм дөнья бик тиз үзгәрә. Вакыйгаларның хәзерге өермәсендә күпләр үз кыйбласын югалтты. Алар Мәккәнең кайда икәнен онытты лар. Дөресен генә әйткәндә, бүген Мәккә безнең өчен Кәгъбә ташы урнашкан җирдән гайре нәрсәне аңлата? Тарихи вакыйгаларнымы? Өметләрнеме? Яки аңлатып булмый торган тагын берәр нәрсәме?

Чын кыйбла билгеле бер урыны булмаган Ходайга мөрәҗәгать итү дигәнне аңлата. Ходай Мәккәдә дә, Иерусалимда да түгел, аның пространствода да, вакытта да үлчәмнәре юк. Ул — бөтен җирдә һәм бар нәрсәдән хәбәрдар...

*«Әгәр Аллаһы теләгән булса иде, әлбәттә, барчагызны бер диндә кылыр иде, ләкин Аллаһы теләгән кешеләрен адаштыра вә теләгән кешеләрен туры юлга сала, кылган эшләрегездән, әлбәттә, соралырсыз, сакланып эш кылыгыз!»* [16:93].

Социологик тикшеренүләр буенча, татар яшьләренең 80% тан артыгы үзен мөселман дип саный, ләкин аларның бары тик 1% ы атнага бер, 4% ы айга бер тапкыр мәчеткә йөри. Татарстанда ачыктан-ачык атеистлар 1% тан азрак, ләкин барлык дини йолаларны үтәүчеләр дә аз. Дин нигезләре (ислам һәм православие) буенча дәресләргә дә бик аз кеше (1—3 %) йөри. Әлеге яңа күренешләрне постсовет феноменына, атеистик пропаганда тәэсиренә сылтап куярга мөмкин булыр иде. Тик бу исламның бөтен планетага хас шушы гомуми проблемаларын аңлатып бирерме соң? Аңлата алмас, мөгаен. Чөнки дөнья һәм аның белән бергә кешеләрнең ихтыяҗы һәм яшәү рәвеше үзгәрде. Иҗтимагый кыйммәтләр һәм мәсләкләр үзгәрде. Без барыбыз да үзгәрдек.

Татарлар мөселманның күзгә күренеп торучы тышкы билгеләрен хәзер элеккечә югары бәяләми. Ислам культураның бер өлешенә әверелгәндер, мөгаен. Әлбәттә, ураза тотмаган, биш вакыт намаз укымаган кешеләрне динсез дип атап буладыр. Әмма ул кешеләр үзләре өчен бу мәсьәләне башкача хәл итәләр. Аларның кыйблалары бар. Ихтимал, алар Коръәнне һәм ислам традицияләрен начар беләләрдер. Бәлки, дин алар өчен этник яктан үзбилгеләнү факторы гынадыр. Бәлки... Ләкин аларның җавап биргәндә сайлау мөмкинлеге булган һәм алар исламны сайлап алганнар. Әбү Хәнифә әйткән: «Без аларны сүзләренә, нәрсәне таный, нәрсәне кире кагуларын күрсәтеп торучы фактларга, дини нормаларга һәм йолаларга карап кына динлеләр яки кяферләр дип кабул итәргә тиеш түгел. Әгәр дә без мәчетләргә йөри торган, безнең кыйблага карап, безнең кебек дога кыла торган кешеләрне очратсак, алар турында башка берни белмәсәк тә, без

аларны диндар кешеләр дип санарбыз... Шуңа күрә без күз алдындагы фактларга карап кына кешеләрне диндар дип кабул итәргә тиеш дип саныйбыз. Гәрчә Аллаһы өчен алар, бәлки, кяферләрдер дә. Башкаларны без, аларда динлелек билгеләре күрмәү сәбәпле, кяферләр дип санарбыз. Ә Аллаһы Тәгалә өчен, бәлки алар динле кешеләрдер...» Моннан да яхшырак әйтеп булмыйдыр, мөгаен.

Ходай өчен ни мөһимрәк — дини йолаларны, гореф-гадәтләрне үтәвеңме яки эчке иманыңмы? Тышкы билгеләрме яки инануның үз формуласын эзләүме? Әлеге сорау риторик булып тоела, әмма ни өчен ислам турында күбрәк йолаларга карап фикер йөртәләр һәм ни өчен исламның асылы кайчак йолаларга гына кайтарып калдырыла?

Йолалар мөһим социаль вазифа үтәгәннәр, аеруча урта гасырлар Гарәбстаны шартларында. Алар ярым кыргый кабиләләрне цивилизацияле тормышка күнектергәннәр. Гарәпләрне мәҗүсилектән чыгарыр өчен кагыйдәләр һәм нормалар кирәк булган, чөнки, мәсәлән, алар кыз бала тууны хурлыкка санап, аларны терелэй җиргә күмә торган булганнар. *«Дәхи Аллаһының кызлары бар, дип ифтира кылалар, мондый кимчелектән Аллаһыны пакь дип белегез! Алар фикеренчә: үзләре сөйгән ир балалар аларга була да, әмма алар сөймәгән кыз балалар Аллаһыга була, имеш. Әгәр ул мөшрикләрнең берсенә «кыз балаң туган» дип сөенеч бирелсә, хатынына ачуланып, дусларыннан оялып йөзе каралып китәдер. Кыз белән сөенеч бирелгәнлектән хурланып кауменнән качадыр, уйлап торадыр: бу кызны хурланып кына асрыйммы икән? Яки терелэтә туфракка күмеп таптыйммы икән, дип. Әгаh булсыннар, кылган эшләре нинди яман кабахәт эштер!»* [16:57]. Бүген бик күп нәрсә эчке культура элементына әверелде һәм кешеләр җәмгыять күзәтчелегенә мохтаҗ түгелләр.

Кеше сурәте ясауны тыю ислам үсешенең билгеле бер чорына бәйле, ул вакытта балбалларга, потларга каршы көрәшергә кирәк булган. Ләкин бүген без кыргыйлар түгел, Әфганстан талиблары кебек, Будда сынын туптан атып ваттыру зарурлыгы юк.

Кыргыйлык һәм ислам үзара сыеша алмый.

Бүген рәсем сәнгате, сынлы сәнгать образлары — югары культура, кеше рухында югары нормалар ныгуы һәм намуслылык билгесе. Ислам намуслылыкка өндәмимени?! Кешеләр һәм хайваннар рәсемнәрен ясауны Аллаһы Тәгалә иҗатына тиңләштерү дип атап, аны тыю архаизм булып күренә. Инде чыннан да мондый дәлилдән чыгып фикер йөртсәк, хайваннарның һәм үсемлекләрнең яңа төрләрен, клонлаштыруны, генетиканы, һәм, гомумән, фәнне дә, теләсә нинди иҗатны да Аллаһы Тәгаләгә тиңләшергә тырышу дип санарга кирәк. Бу исә чып-чын мәгънәсезлек.

Ислам кешеләрне кыргыйлыктан чыгарыр өчен иңдерелгән. Тәкъвалык кешеләрнең цивилизацияле, культуралы, белемле булуыннан гыйбарәт. Йолалар кешеләрне даими рәвештә төп кануннарга кайтаралар, аларны хакыйкать эзләүгә юнәлтәләр. Аларның вазифасы шул. Ә хакыйкать үзе прогресстан, ягъни фәннәр, технологияләр, техника үсешеннән, белемне күтәрүдән, гадел җәмгыять һәм уңышлы икътисад булдырудан, әхлакый югарылыктан гыйбарәт.

Тыюларның һәм йолаларның кайберләре XXI гасырда үз мәгънәләрен югалттылар. Мөселман күрсәтмәләре буенча терлекне кулдан сую тикмәгә генә түгел, кешеләр сыйфатлы ит ашасыннар өчен уйлап табылган. Бу Ходайга түгел, үзеңә кирәк. Кеше әлеге йола ярдәмендә Аллага хезмәт итми, үзенә игелек эшли. Әгәр дә безнең заманда терлек конвейер ярдәмендә сыйфатлы итеп суела икән, кеше дә оттырмый, димәк, Аллаһы Тәгалә дә канәгать кала. Коръән йолаларның физик формасына карап түгел, рухи мәгънәсе аркасында кыйммәткә ия. Әйтелгән: *«Чалган дөяләрегезнең итләре вә каннары Аллаһыга ирешмәс, ләкин сездән Аллаһыга тәкъвалык вә изге гамәлләр ирешер...»* [22:37].

Дини йолалар кеше тормышын катлауландыру өчен түгел, җиңеләйтер өчен бирелгән ләбаса. Ислам — кысан аяк киеме түгел. Ул — кешеләрнең сәләтләрен ачып бирү ысулы. Коръән буенча, пәйгамбәр *«аларда булган авырлыкны вә диннәрендәге каты хөкемнәрне алардан бетерер»* [7:157] өчен җибәрелгән.

Бүген нидер тыюдан бигрәк, уңай ниятләр мөһимрәк. Кеше күп очракта куркудан да яки бүләк өчен дә түгел, ә рухи нияттән чыгып, яшәүнең иң яхшы рәвешен сайларга тырыша. Мин, цивилизацияле дөнья кешесе, Әфганстан кабиләләре дәрәҗәсенә төшеп, аларга тигезләшә алмыйм бит инде. Бәлки, анда йолалар фән һәм белемгә карата мөһимрәктер. Татарлар кыз балаларын җиргә күммиләр, таш сыннарга, ошатмаган очракта да, туптан атмыйлар. Талиблар — кыргый, һәм шуңа күрә тәкъва түгел.

Артта калганлык һәм тәкъвалык үзара сыеша алмый, алар капма-каршы нәрсәләр. Урта гасыр шәригате буенча яшәүче Судан халкы минем белемле, мәгариф һәм фәнни тикшеренүләр системасы үсешендә үз традицияләрен булдырган халкымнан тәкъварак дигән фикер белән килешү мөмкин түгел. Ислам кешеләрне кыргыйлыктан чыгарып, аларны үстерү, гаделлек юлына бастыру максатында барлыкка килгән.

Тәкъвалыкка беренче адым — белем алу, ә догалар һәм йолалар белемнең әһәмиятен аңларга ярдәм генә итәләр. Котылу чарасы йолаларда түгел, прогресста. Муса Бигиев «Инсаннарның гакыйда Илаһияларына бер назар» дигән хезмәтендә болай дип язган: «Дин мәсьәләсендә рәсмилек юк. Дин ниндидер формаль

тышчага төренсә, кешелек яшәеше өчен мәгънәсен югалта. Кешене явызлыктан һәм бозыклыктан читләштерүче, аны игелекле эшләргә этәрүче — шәригать олылаган дин шул була. Шәригать күзлегеннән чыгып карасаң, кеше яшәеше өчен әһәмияте булган дин яхшы. Әгәр дә диннең кеше тормышына йогынтысы юк икән, андый дин, андый шәригать файдасыз». Хакыйкать ул — йолаларны үтәп, хиҗабка төренеп, сакал үстереп җәннәттә үзеңә урын тәэмин итү түгел. Ул матди дөньяның каршылыгын җиңүдә, җәмгыятьне рациональ коруда, кешеләрнең тормышын яхшыртуда, гомумкешелек акылының бер өлешенә әверелүче уңай тәҗрибә туплаудан гыйбарәт.

Матди дөньяга каршы аны рухилаштыру өчен көрәш кешене коткару предметын билгели дә инде. Әгәр дә бу эштә йолаларның файдасы бар икән, алар булсыннар, әмма җәмгыятьнең культура дәрәҗәсе югары һәм кешеләр фән һәм белемнең Ходай Тәгаләгә якынаюда әһәмиятен аңлыйлар икән — йолаларның мәгънәсе икенче планга күчә, алар кешенең шәхси эше, өстенлекләрне шәхсән билгеләү мәсьәләсенә кайтып кала. Әгәр дә ниндидер сәбәпләр аркасында йолаларны үтәү катлаулы икән, бу очракта аларның максатка ярашлыгына һәм игелекле гамәлләргә юнәлеш тоту мәгъкуль. Пәйгамбәр әйткән: «Чынлап ки, дин ул — җиңеллек, диндә чама белми тырышкан кеше оттырачак. Тураегыз, һәм якын килегез, һәм шатланыгыз»,— дигән.

Ходай кеше үти алмый торганны таләп итми, Ул рәхимле һәм кешегә үтәргә кыен булган нәрсәләр йөкләми. Мөмкинлекләр чигеннән чыгып нәрсәдер йөкләү — тиранлык. Коръәндә язылганнар барысы да кешенең көченнән килерлек, җиңел һәм файдалы нәрсәләр. Пәйгамбәр әйткән: «Җиңеләйтегез, катлауландырмагыз, куандырыгыз, күңел кайтармагыз».

Аллаһы Тәгаләгә безнең сукырларча табынуыбыз һәм йолаларны чамадан тыш тырышып үтәвебез кирәк түгел. Пәйгамбәр әйткән: «Аллаһы динлелекне күрсәтүдә чамадан тыш табынуны һәм ахыр чиккә җитүне яратмый». Ул монахларча яшәүне хупламаган, йолаларны үтәүдә адәм баласы булдыра алганнан артыгын таләп итмәгән, гыйбадәт кылу бәрабәренә дөнья рәхәтлекләреннән баш тартучыларны өнәмәгән. «Мәгарәләр, тау башлары һәм чүлләр шикелле ерак һәм кешесез җирләрдә яшәмәгез. Андый җирләрдә яшәү кабердә яту белән бер»,— дигән ул. Синең шәхсән котылуың ул — җәмгыятьне хәрби, сәяси, экологик, рухи катастрофадан коткару дигән сүз.

Мөхәммәд пәйгамбәр йолаларга зур игътибар биргән, ләкин шул ук вакытта шактый сизгер дә булган. Ул: «Кирәкле белем алуга киткән бер сәгать Аллаһы өчен дога кылып үткәргән бер көнгә караганда яраклырак»,— дигән. Ә бит дога кылу исламның беренчел нигезләренең берсе булып санала. Димәк, чын мөселман өчен белемнән дә өстен нәрсә юк. Өстәвенә Коръәнне белү генә түгел, гомумән, төрле фәннәрне белү күздә тотыла. Пәйгамбәр әйткән: «Бишектән алып кабергә кадәр гыйлем эстәгез. Кытайга кадәр барып булса да белем алыгыз. Бу дөньяда рәхәт күрергә теләгән кеше сәүдә итсен, теге дөньяда рәхәт күрергә теләгән кеше сабырлык һәм тәкъвалык эзләсен, ә ике дөнья рәхәтен күрергә теләгән кеше — аны белем алуда һәм гыйлемдә эзләсен».

Суны баскан килеш эчәргәме яки утырган килеш эчү дөресрәкме дип бәхәсләшүгә бик күп вакыт сарыф итәргә, бу турыда диссертацияләр, китаплар язарга, конференцияләр үткәрергә мөмкин. Нәтиҗәдә кайсы якның хаклы икәнен дә исбат итәргә була, ләкин моның исламга нинди мөнәсәбәте бар соң? Пәйгамбәр чыннан да су эчкән, бары шул гына.

Хикмәт пәйгамбәрнең киенү рәвешендә, йолаларны нинди вакытта һәм ничек үтәгәнендә түгел. Хикмәт — аның боларны ни өчен эшләгәнлегендә. Йолалар, зәкят, мирас хокукы һәм шәригатьнең башка нормалары җәмгыять тизрәк алга китсен өчен кирәк булган. Иң мөһиме шушы. Хикмәт мирасның күпме өлеше ир балага, күпме өлеше кыз балага тиешлегендә түгел, ә мирасны тапшыруның тотрыклы һәм гадел булырга тиешлегендә. Үткән заманда гадел булган нәрсә бүген дә һәр очракта гадел була алмый. Безнең заманда кыз балаларны ир балалардан ким күрер өчен сәбәпләр юк, алга киткән җәмгыятьтә хезмәтне җенес билгеләренә карап бүлмиләр.

Исламда нормалар үзгәрә, ә төп максат — гаделлек сакланып кала. Бөек дин билгече Әбу Хәмит әл-Газали болай дигән: « Бер сәгать гаделлек йөз ел дога кылуга тиң». Коръән «үзегезгә каршы юнәлгән булса да» гаделлекне сакларга өнди.

Зәкят — үз табышыңның бер өлешен җәмгыятькә бирү белән түгел, ярлыларның кимүенә, бурычларның түләнүенә, җәмгыятьтә тулаем муллык артуга, байлыкка мөккиббәнлекнең, нәфеснең, саранлыкның, акча җыючылыкның кимүенә ярдәм итү белән Ходайга яраклы гамәл. Болар барысы да җәмгыятьне гаделрәк, димәк, яшәүгә сәләтлерәк итә.

Зәкятне колларны азат итүгә тоту нәрсәне аңлата? Моның бернинди дә мәгънәсе юк, чөнки хәзер коллар юк. Ләкин исламның төп мәгънәсе үзгәрми — җәмгыятьне тотрыклырак, кешеләр тормышын мулрак итү. Пәйгамбәр: «Һәр игелекле гамәл — сәдака ул»,— дигән. Менә кайда исламның асылы! Зәкят — игелекле гамәл, ә теләсә нинди игелекле гамәл — ислам ул.

Тәкъвалыкның мәгънәсе хәер бирүдә түгел, ә ярлылыкны бетерүдә. Ярлылыкка каршы көрәшүнең башка ысуллары юк икән, димәк, бу очракта хәер бирергә генә кала. Әгәр дә байлыгың башка кешеләрне дә баета икән, бу — игелекле эш, аның максаты зәкят бирү максаты белән бер үк! Игелекле эш — сәдакага тиң. Кеше игелек кылган саен Аллаһы Тәгаләне искә төшерә.

> *«Сезне ахирәт өчен кирәк гамәлләрдән гафил кылды, алдады, мәхрүм итте дөнья малын күбәйтү белән мактанышуларыгыз. Хәтта үлеп кабергә кергәнегезгә хәтле, алдануыгызны дәвам иттердегез. Юк, алданмагыз, әле дөньяга ышанып тыныч кына яшәсәгез дә, тиздән белерсез алданганыгызны!»* [102:1 — 8].

Ислам өйрәткәнчә, байлык үзмаксат була алмый. Пәйгамбәр әйткән: «Әгәр дә кешенең алтын сибелгән бер үзәне булса, ул аның икәү булуын теләячәк, икәү булса — өченчесен... Аны ахыр чиктә бер уч туфрак кына тынычландырачак»; «Якыннары ач калган вакытта туйганчы ашый алган кеше динле түгел». Җәмгыять мәнфәгатьләре белән яшәү — хакыйкать юлы. Ходай бурычлар җыелу, чамадан тыш шәхси байлык һәм ярлылар арту аркасында җимерелүне булдырмый торган икътисади система төзергә өндәгән. Шуңа күрә ул рибачылыкны кире каккан: «*Янә Аллаһ тарафыннан каты тыелган булсалар да, риба, ришвәт алулары һәм кеше малын юлсыз ашаулары сәбәпле хәләл нәрсәләрне аларга хәрам кылдык, һәм яһүдләрнең кяфер булганнарына рәнҗеткүче газапны әзерләдек»* [4:161]. «Алтын бозау»га табыну теләсә нинди рәвештә — мал-мөлкәт, күчемле яки күчемсез милек җыюмы; банкларда акчаны хәрәкәтсез яткыра торган счетлар ачумы; тормышыңда артык муллык булдырумы — барысы да мәҗүсилек. «Безнең хәзерге тормышка һәм үзебезнең таш балбалларга (йортлар), тимер потларга (машиналар), кәгазь аллачыкларга (дипломнар, сертификатлар) киткән вакыт, мәхәббәт һәм энергия күләменә карагач,— дип яза Фәрит Исак,— мин җәберлек караңгылыгыннан Муса тарафыннан ирек яктысына чыгарылган израильлеләрнең акылсызлыгына гаҗәпләнмим. Алар белән безнең арада аерымлык шунда гына ки, «алтын бозау» культына нигез салган Самири берьялгызы һәм беркатлы эш итсә, капитализм һәм табыш җыю идолларын бүген бөтен бер сыйныфлар ясый, аларның бар тормышы теге яки бу рәвештә табыш алу тирәсендә бөтерелә». Капиталистлар гына түгел, хәтта руханилар да кайвакыт матди якны рухи яктан ныграк кайгырта. Алар ярлы түгел. Аларны дәрвишләр дип атап булмый. Нәфесне, матди дөньяны җиңү, аңа рухият өстәү байлыктан шәхси тормышың өчен түгел, кешеләргә хезмәт итүдә файдалануны күздә тота.

Дини тәгълимат китапларын укыганда, өстеңә хәзерге заманга берничек тә бәйле булмаган терминнар, чамадан узган схоластика ишелеп төшә. Мәхмүт Топташның «Аллага ышану һәм аның алты нигезе» дигән китабында фәрештәләргә ышануга, аларның көчләренә, үзенчәлекләренә, бурычларына анализ ясала, фәрештәләр төркемнәргә бүленә. Дин галимнәре компьютерлар һәм телефоннар кулланмый, бервакытта да самолетларда очмый икән дигән тәэсир кала. Алар бу әйберләрнең кем тарафыннан ясалуы һәм бу өлкәдә ислам илләренең Европа илләре белән конкурентлыкка ничек чыга алулары турында уйланмыйлар. Аларның һәммә сорауга да җаваплары бер — дога укырга кирәк. Самолетлар дога уку аркасында оча диярсең! Фикъһе аэродинамиканы алыштыра алмый лабаса. Бер хәдис турында тау-тау китаплар язалар, ә хәзерге университетларның нинди булырга тиешлеге, мөселманнарга алга китәр өчен нинди фәнни юнәлешләрне үстерергә кирәклеге турында ләм-мим. Дин белгечләре чалбар балагының озынлыгы темасын җентекләп тикшерә алалар, ә заманча технологияләр турында бер сүз дә әйтмиләр. Катлаулы сорауларның барысына да җаваплары бер: «Ислам — уй-фикерне дөресләүче иман, йөрәкне пакьләндерүче гыйбадәт, җанны сафландыручы әхлак, гаделлекне раслаучы законнар чыгару, тормышны бизәүче традицияләр һәм культура». Алайса, ни өчен дөньяда иң артта калган илләр — чын мөселман илләре? Самолетларны кем ясарга тиеш? Христианнармы?

Ислам күп гасырлар буе бик зур территориядә хакимлек иткән, әмма хәлифәтләр эчке низаглар аркасында җимерелгәннәр. Шуңа да карамастан дин белгечләре моның сәбәпләрен хәзергәчә тыштан эзлиләр: башка илләрдәге дошман көчләрне — сионистларны, бөтендөнья христианлыгын һәм капитализмны гаеплиләр. Әлеге күренеш хәтта гаҗәп кенә дә түгел. Бу — исламның кешеләргә ни өчен җибәрелгәнен аңламау, исламның гамәли ягын белмәү. Аллаһы Даутка *«байлык һәм пәйгамбәрлек бирде һәм аңа үзе теләгән нәрсәләрне өйрәтте»* [2:251], ягъни Ул аңа файдалы белем биргән. Әгәр дөньяви законнар тормышны яхшырак, гаделрәк итәләр, икътисадны көчәйтәләр, ярлылыкны киметәләр икән, димәк, алар Ходайга яраклы.

Мәгариф системасын үзгәрткән күренекле татар реформаторы Габдулла Буби болай дип язган: «Безнең бурыч бер үк вакытта ике юлдан: рухи һәм матди юнәлешләрдә бару, дини нәрсәләрне дә, дөньяви нәрсәләрне дә берьюлы алга этәрү». Дөньяви нәрсәләр исламга чит түгел. Һәм дә пәйгамбәр тормышына бәйле һәрнәрсәне дә дини дип санарга ярамый. Ул, мәсәлән: «Тешләрегезне чистартыгыз»,— дигән. Бүген теләсә

кайсы табиб кына түгел, хәтта реклама да шул киңәшне тукый. Балалар, сөйләшергә өйрәнгәнче, тешләрен чистарта башлыйлар. Пәйгамбәр бик күп гамәли киңәшләр биргән һәм аларның күбесе мөселман булу-булмауга карамастан, хәзерге заман кешесе өчен нормага әйләнгән. Моңа охшашлы нормаларда, әйтик, чалбар балагы озынлыгында, суны басып яки утырып эчүдә, сакал үстерүдә яки үстермәүдә, хиҗаб киюдә һәм башкаларда бернинди дини төсмер дә юк, болар — саф дөньяви нормалар. Ислам, культура буларак, дини нәрсәләрне дә, дөньяви нәрсәләрне дә үз эченә ала. Ислам дөньявилыкка каршы тормый, аны кысрыкламый, аңа каршы көрәшми, ислам иман һәм белем, мәңгелек һәм мизгел, дини институтлар һәм дәүләт, аерым кеше һәм җәмгыять, рухи һәм матди нәрсәләр арасында гармония тудыра.

Хәзерге заман цивилизациясе кешеләрдә ашауда һәм спиртлы эчемлекләр эчүдә чама хисе тәрбияли, сыйфатлы ит ашарга һәм гигиена кагыйдәләрен үтәргә киңәш итә. Болар мөселманнарга гына хас билгеләр түгел, алар мөселман өммәте кысаларыннан чыгып, инде күптән гомумкешелек нормаларына әйләнделәр. Культуралы теләсә кем аларны үтәп килә. Йолалар динле кешене дин тотмаучыдан аеручы билге була алмыйлар. Әгәр дә кеше: «Аллаһы Тәгаләдән башка Тәңре юк, Мөхәммәд — Аллаһның пәйгамбәре»,— дип әйткән булса, ул — динле кеше, ә йола һәм гореф-гадәтләр аның дингә ышануын билгеләмиләр, ә бары тик ныгыталар гына.

> *«Дәһи Аллаһ алдына үз гөнаһын йөкләп баручы кеше башка һичбер кешенең гөнаһын йөкләп бармас»* [17:15].

Цивилизацияле җәмгыятьтә йолаларның мәгънәсе үзгәрә. Хатын-кызларга яулык бәйләргә, ир-атларга сакал үстерергә ярый. Бу аларның шәхси эше, бу — тышча, аның эчендә диндарлык та, шулай ук Аллага ышанмау да яшеренергә мөмкин. Исламның асылы анда түгел.

Мөселман дин белгечләре хиҗаб киюне кешенең, ягъни ир-атның, начар табигате белән аклыйлар. Рукайя Максуд язганча, мөслимәләр «тыйнак киенүне өстен күрәләр, ачык һәм заманча киемнәр ирләрнең түбән инстинктларын аздыра дип саныйлар, чөнки, алар фикеренчә, мондый киемнәр ирләрнең хатын-кызларга җәмгыятьнең тигез хокуклы һәм бәйсез әгъзалары буларак түгел, ә «җенси теләк объекты» буларак карашын ныгыта. Алар ир-атлар игътибарларын иң элек хатын-кызның тәненә түгел, акылына һәм холкына юнәлдерүен телиләр». Мондый мантыйк хәтта гаҗәп кенә дә түгел, чөнки тормыш бит җенси мөнәсәбәтләрдән генә тормый, ә ир-атларны үз-үзен кулда тота алмый торган хайваннар рәвешендә күзалларга ярамый. Барлык ирләр дә азгын түгел, һәм азгын хатын-кызларның да телгә алырлык дәрәҗәдә күп түгеллеге көн кебек ачык. Хайвани инстинктлар мантыйгын ислам принцибы дәрәҗәсенә күтәрергә ярамый.

Татар хатын-кызлары арасында хиҗаб кию һәм паспортка яулык бәйләп фотога төшү хокукы өчен бөтен бер хәрәкәт барлыкка килде. Аларның моңа хокукы бар һәм дәүләт аларны чикләмәскә тиеш. Ләкин аларның ныклыгы, үзсүзлеге, ихтирамга лаек булса да, файдалырак кулланылыш таба алыр иде. Әгәр дә инде алар шулкадәр тәкъва икән, димәк, аларга, «Әхзаб» сүрәсенең *«Вә өйләрегездә торыгыз»* дип әйтелгән 33 нче аяте нигезендә, судларда йөрергә ярамый. Димәк, алар өйдә генә торырга тиешләр. Алар чит ирләр белән бары тик пәрдә аша гына аралашырга тиеш [33:53] һәм фатирларының хатын-кызлар ягында гына яшәргә тиешләр. Кайчандыр татар хатын-кызлары мөселман Көнчыгышында иң гыйлемле һәм иң алга киткән хатын-кызлар булып саналганнар. Бүген исә алар моның киресен исбатларга телиләр, күрәсең.

Урта гасырларда хатын-кызга милек итеп караганнар һәм аларны, милек буларак, кул сузулардан саклаганнар. Коръән буенча ир кешегә үзенең кол хатын-кызлары белән ләззәт алу гөнаһ түгел, моны чит хатыннар белән эшләргә ярамый, чөнки чит хатыннар аның милке түгел. Шәригать буенча, әхлак бер генә хатынга тугры булуда түгел, ә чит хатынга кагылмауда. Шәригатьтә урлашуның һәм зина кылуның бер төр җинаятькә — хөддәгә каравы очраклы түгел. Милек — җәмгыятьнең какшамас нигезе булып санала, аңа беркем дә кул сузарга тиеш түгел. Шул рәвешчә, җәза катылыгы да урланган әйбернең кыйммәтеннән түгел, урлашу фактының үзеннән чыгып билгеләнә.

Кием, үзенең көнкүреш функциясеннән башка, әле матурлык чагылышы булып, кешенең эчке дөньясын, аның фантазиясен дә күрсәтеп тора. Бу — матди әйбергә рух өрү, матди дөньяны җиңеп чыгу шикелле дә хәтта. Матурлык Коръән таләп иткән тыйнаклыкка һич каршы тормый. Пәйгамбәр раславынча: «Аллаһы Тәгалә матур һәм ул матурлыкны ярата». Татар хатын-кызлары арасында хәтта иң «исламлы заманнарда» да, примитив хиҗаб кию гадәте булмаган, чөнки мода һәм дин — мөстәкыйль күренешләр. Мәдрәсәдә чиста мөселман кануннары буенча тәрбияләнгән әбием татарлар өчен ят булган әлеге киемне бервакытта да кимәде. Хиҗабның барлыкка килүе гарәпләрнең этник традицияләре аркасында килеп чыккан, ком бураннары еш булган чүлләрдә аларга андый кием уңайлы булган. Турысын гына әйткәндә, хиҗаб — бернинди зәвыксыз тегелгән ямьсез кием. Ул татар хатын-кызларының традицион милли киеме яки хәзерге заман модасы белән чагыштырып караганда, берәүгә дә бернинди дә өстенлек бирми. Хәер, бу да

үзенчә мода һәм теләсә нинди мода шикелле яшәргә хаклы. Кем өчендер пәрәнҗә — дин символы, ә кемдер — нудист. Аларның кайсысы җәннәткә керер? Күпчелек беренчесе дияр. Ләкин мондый хөкем чыгарырга кемнең хакы бар? Әйтелгән: *«Ий сез, ачык дәлилләрне ригая кылмаучы кире кешеләр, диндә дәлилсез низаглашуларыгызның хөкеме Аллаһыга кайтарылыр, Ул үзе хөкем итеп аерыр: кемнеке — дөрес, кемнеке — ялган, шунда мәгълүм булыр»* [42:10]. Сабыр бул һәм гафу итә бел, шул вакытта сиңа да Аллаһ рәхмәте төшәр.

Әлбәттә, кешеләр өчен символлар да мөһим. Алар — таяну нокталары. Казан Кремлендә Кол Шәриф мәчетен торгызуның зарурлыгы турында фикер алышканда, бу изге эшкә мин дә үземнең тыйнак өлешемне керттем. Русия ислам университетын оештырганда, миңа Татарстан мөфтие Госман хәзрәт Исхаков һәм мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин имзалары белән рәттән кул кую бәхете насыйп булды, әмма йолаларга мин шәхсән хәтта яшерен эш, күңел эше дип карыйм, аны кешегә күрсәтеп эшләргә кирәкми дип уйлыйм.

Кешелек үзенең үсешендә озын юл узды һәм бу вакыт эчендә кешенең табигате дә үзгәрде. Ул гарәп чүлләренең кыргые түгел инде хәзер. 1400 ел эчендә ислам кеше табигатенә файдалы тәэсир ясый алмаган, аның инстинктларын яхшырта алмаган дип фаразлау исламның көчсезлеген тануга тиң булыр иде. Мөселман хатын-кызлары ир-атларга бозык хайваннарга караган кебек түгел, кешеләргә караган кебек карасалар, күп кенә традицияләрнең искергәнлеген күрерләр иде. Ир-атларга да хатын-кызга биек койма артында чит күзләрдән яшереп сакланырга тиешле милек итеп түгел, ә тигез хокуклы шәхес итеп карау зыян итмәс иде.

Хатын-кызга икенче сортлы зат кебек караш исламга иудаизмнан һәм христианлыктан үтеп кергән. Европа әкренләп моннан ераклашты, ә мөселман илләре әле һаман да бу карашка ияреп баралар. Хатын-кызга иң беренче гөнаһ кылучы итеп карарга ярамый. Коръән буенча Иблис Адәм белән Хаваны бер үк вакытта аздырган: *«Иблис, бу агач җимешен ашасагыз, җәннәттә мәңге каласыз, дип, аларны алдады, алар, Иблис сүзенә ияреп, җимешне ашап алдандылар. Иблис аларны җәннәттән чыгарып, андагы нигъмәтләрдән аерды»* [2:36]. Алай гына да түгел, «Та Һа» сүрәсендә нәкъ менә *«Адәм Раббысына гөнаһлы булды, дошманының ялган сүзенә ияреп, максатына ирешүдән коры калды»* диелгән. [20:121]. Ахыр чиктә, ир-ат һәм хатын-кыз беренче гөнаһны кылуда бертигез җаваплы.

Коръәннең «Хатын-кызлар», «Нур», «Әхзаб» сүрәләрендәге аятьләре хатын-кызның тигезсезлеген ныгыталар. Алар Мәдинә чорында язылганнар. Әлеге чорга кадәр шәригатьнең хатын-кызларга карата кагыйдәләре дөньяда иң алдынгы закон булган. Ләкин ул чорлардан соң цивилизацияле илләр бик алга киттеләр, ә шәригать һаман бер урында таптана. Хәйдәр Баш хатын-кызлар хокукы турындагы мәсьәләне тикшерүне мәгънәсез дип исәпли. «Көн тәртибенә хатын-кызларның хокукы, аңа хокуклар бирү кебек проблемаларны кую тамырдан ук дөрес түгел, чөнки хатын-кызга хокукларны бирәү дә бирә алмый, ул барлык хокукларга ия булып туа. Теләсә кем тумыштан ук яшәүгә, милеккә, намуска хокуклы». Яхшы әйтелгән, ләкин Коръән буенча коллар да булырга мөмкин. Алар кешеме яки кеше түгелме? Шәригать буенча алар дөя белән бер дәрәҗәдә милеккә тиңләштерелгән. «Һәркем тумыштан ук ирекле» дигән принципның аларга да кагылуы мөмкинме? Кайбер дин галимнәре уйлаганча, шәригать гади нәрсә түгел. Хатын-кызлар хокуклары мәсьәләсен тикшерүнең мәгънәсе бар. Иҗтиһад кирәк.

Ирләрнең һәм хатын-кызларның хокуклары төрлелеген яклау өчен китерелә торган тагын бер аргумент — аларның җәмгыятьтәге функцияләре аерымлыгын, димәк, хокукларының да төрлелеген билгеләүче физиология. «Хатын-кызны һәм ир-атны тигез дип санау, асылда, алма белән грушаны тиңләштерү белән бер,— дип дәвам итә Хәйдәр Баш.— Бу исә әйберләрнең табигатенәкаршы килә, чөнки хатын-кыз һәм ир-ат психологик яктан да, физиологик яктан да тигез түгелләр. Үз табигатьләре буенча төрле булган кебек, алар бурычлары һәм җаваплылыклары буенча да бер-берсеннән аерылып торалар». Ир-атларның үзләре турында ук шулай әйтергә мөмкин — алар да физик мөмкинлекләре һәм интеллектлары буенча бер-берсеннән аерылалар.

Физиология мирас, аерылышу яки башка хокуклар мәсьәләсен хәл итүдә нигез булып тормый. Кеше кеше инде ул. Ни өчен бер ир кеше шаһитлыгына каршы ике хатын-кыз шаһитлыгы таләп ителә соң? Моны хатын-кыз табигате буенча йомшак күңелле, кызганучан һәм гаделлек таләпләреннән чигенүе мөмкин дип дәлилләрләр. Әмма бу — субъектив фикер. Хатын-кызның катылыгына һәм үз сүзендә нык торучанлыгына да һәм, киресенчә, ир-атның йомшаклыгына да меңләгән мисал китерергә мөмкин.

Ислам бурычларының берсе дөньяны гаделрәк итүдән гыйбарәт. Полигамия хатын-кызга карата гаделлек чагылышы булып санала. Йосыф әл-Кардави бу хакта болай дип яза: «Шәригать ирнең барлык хатыннарына да ире тарафыннан тәрбиягә, торакка, киемгә тигез хокук гарантияли. Полигамиягә бәйле гаделлек шушы була инде. Чынлап та, кайбер ир-атлар Аллаһ аларга бурыч итеп биргән гаделлекне үтәмиләр. Ләкин начар кулланылыш принципларны нигездә гамәлдән чыгару дигән сүз түгел». Полигамия, мирас хокукы яки аерылышу процессы кебек үк, хатын-кызны ир-ат белән тигезсез хәлгә куя, ә хокук тигезлегеннән башка гаделлек була алмый. Әгәр кешеләрнең хокуклары тигез түгел икән, димәк, дөньяда гаделсезлек, димәк,

динсезлек саклана. Барлык кешеләр дә тумыштан ирекле һәм тигез. Биредә физиологиянең яки нәселнең, расаның яки телнең, диннең яки илнең катнашы юк. Бөтен кешене дә бертөрле итеп булмый, әмма бөтен кешенең дә хокуклары тигез булырга тиеш.

Йосыф әл-Кардави дәвам итә: «Табигате буенча хатын кыз үзен саклый, яклый, кулында тота торган ир-ат кайгыртуында булырга тели». Коръәндә ир-атның хатын-кыздан өстенлеге ир-ат хатын-кызның иминлеген тәэмин иткән һәм тәрбия иткән очракта гына танылa [4:34]. Әлеге функцияләрне җәмгыять үз өстенә алган һәм хатын-кыз икътисади яктан бәйсез булган илләрдә исә андый өстенлеккә нигез калмый.

Хәзерге заманда хатын-кызлар еш кына ир-атлар белән бер үк дәрәҗәдәге җаваплылык йөген тартып баралар. Бу хәзер нормага әйләнде. «Хатын-кызның ир-ат эше башкаруын һәм аның җилкәсенә ир-атка тиеш йөк салынуын хокук дип атарга ярыймыни?» — дип яза Хәйдәр Баш. Европа илләре тәҗрибәсе мондый дәлилләрне һәр адымда кире кагып бара. Авыр физик хезмәт ир-ат җилкәсенә салынган урта гасырларда гына хатын-кыз кайгыртуга мохтаҗ иде һәм бу гадел хәл иде. Бүген хезмәт рәвеше үзгәрде, ул күбрәк акыл хезмәтенә әверелеп бара. Мәсәлән, табиб, укытучы кебек һөнәрләрне ир-ат һөнәрләре генә дип әйтеп булмый. Мондый хезмәт хатын-кызны кимсетергә мөмкинмени? Әлбәттә, юк. Бу — игелекле хезмәт, ул кешеләргә иминлек, сәламәтлек, белем китерә.

Хакыйкать шунда ки: хатын-кыз хокуклары буенча тарихи шәригать бүгенге көндә кулланыла алмый, чөнки ул башка аудиториягә — Мәдинә җәмгыятенә юнәлдерелгән. Мәккәдә язылып бөтен кешелеккә һәм мәңгелеккә бирелгән аятьләрдә хатын-кыз һәм ир-ат арасында аерымлыклар юк. Бу — XXI гасыр шәригатенең төп принцибы булырга тиеш. Муса Бигиев язган: «Хатын-кызларның хокуклары никадәр камилрәк, аларның абруйлары никадәр югарырак булса, җәмгыять системасы шулкадәр көчлерәк булачак». Ә мөселман җәмгыяте көчле булырга тиеш.

> *«Янә әйт: «Ий кешеләр! Ошбу Коръән Раббыгыздан килгән хак сүзләрдер, туры юл, вә гадел хөкемнәрдер, теләгән кеше Коръән белән гамәл кылып мөэмин булсын вә теләгән кеше Коръән белән гамәл кылмасын да кяфер булсын!»* [18:29].

Пәйгамбәр әйткән: «Бөтен дөнья дога кылу урыны итеп яратылган». Өенең бер бүлмәсендә яки почмагындамы, хәтта компьютер алдында, фәннәр белән шөгыльләнгәндәме — теләсә кем теләсә кайда Аллаһы Тәгалә белән аралашу урыны таба ала. Һәркем Аллаһы Тәгаләгә мөнәсәбәтен үзе билгеләргә ирекле.

«Аллаһы Тәгаләдән башка Тәңре юк, Мөхәммәд — Аллаһның пәйгамбәре» дигәнне таныган кеше динле кешегә әйләнә. Йолалар һәм гореф-гадәтләр динне билгеләми, диннән килеп чыга. Алар икенчел. Әбү Хәнифә болай дип язган: «Динле кешеләрнең дога кылырга, зәкят түләргә, ураза тотарга, хаҗга барырга, Аллаһны истә тотарга теләгеn аларның Аллага ышануы тудыра, киресенчә түгел: дога кылу, зәкят түләү, ураза тоту, хаҗга бару аркасында Аллаһка ышану теләге тумый. Бу шулай, чөнки алар иң элек Аллаһка ышандылар, аннан соң гына гамәлләргә тотындылар. Дини бурычлар Аллаһка ышануга түгел, Аллаһка ышану аларны дини бурычларны үтәргә өндәде». Берәү дә кешене хөкем итә, син шундый булырга тиеш дип күрсәтмә бирә алмый, бигрәк тә, син мөселман түгелсең, дип әйтә алмый. Әбү Хәнифә язган: «Кешеләр дингә ышануда бер-берсеннән аерылмыйлар, бер-берсеннән яхшырак була алмыйлар, алар үзләренең кылган гамәлләре буенча бер-берсен узып китәргә һәм дини бурычларын үтәү буенча бер-берсеннән аерылырга мөмкиннәр».

Хакыйкать шунда ки: динлелек һәм динсезлек мәсьәләсен Ходай Тәгалә бары тик үзе генә хәл итә. Бу мәсьәләдә арадашчылар булу мөмкин түгел. Хакыйкатькә таба юлда руханилар автомобиль юлындагы күрсәткеч такталар функциясен үтиләр, әмма алар «ятып торучы полицейскийлар» ролендә булмаска тиеш.

Ислам белгечләре дини белем алырга ярдәм итә алалар, ләкин һәркем дингә юлны мөстәкыйль рәвештә үзе үтәргә тиеш. Ахыр чиктә, Ходай Тәгалә безне үз янына алганда, яныбызда имам да, мөфти дә, дини бергәлек тә булмаячак. Анда адвокатлар булмаячак.

> *«Һәм куркыгыз Кыямәт көненнән, ул көндә һичбер зат икенче затка бер эш белән дә ярдәм итә алмас! Ул көндә шәфәгать итү кабул ителмәс һәм газаптан котылу өчен һичнәрсә алынмас»* [2:48].

Кыямәт көнендә хөкем кылу хокукы бары тик Ходай Тәгаләгә генә бирелгән. *«Аларга анда Аллаһыдан башка хуҗа һәм шәфкать итүче булмас»* [6:51]. Янында атаң да, анаң да, остазың да булмас, чөнки ул — Кыямәт көне. Берәү дә чит кеше гөнаһларын үзенә ала алмас, һәркем үзе өчен генә җавап тотар: *«Һәрбер кеше ни кылса да, үзе өчен генә кыладыр һәм гөнаһ йөген йөкләүче кеше башка һичбер кешенең гөнаһ йөген йөкләп алмас»* [6:164]. Шулай булгач, нишләп бу тормышта адвокатлар булырга тиеш ди?

Аллаһ бөтен кешене дә диндар итә алыр иде, Аның кодрәте киң. Әйтелгән: *«Әгәр Аллаһ теләгән булса иде, әлбәттә, барчагызны бер диндә кылыр иде»* [16:93]. Ләкин Ул алай эшләмәгән. Ул кешеләрне хак юлга бастырыр өчен пәйгамбәрләр сайлаган, ә кешеләрне үз ихтыярларына калдырган.

Кешеләр тәкъдир коллары түгел. Ходай Тәгалә кешегә туганда ук динсез булырга дип язып куя алмый, ул һәркемгә сайлау мөмкинлеге калдыра. Кеше динле яки динсез, мөселман яки башка дин кешесе булырга яки йолаларны үтәмәскә мөмкин. Җәза бирү яки бүләкләү — Аллаһ кодрәтендә. Тәкъдирнең хак юлны сайлау хокукына катнашы юк. Кеше, үлеме кайда булса, шунда үлә, ләкин гомерен ничек үткәрүе һәм үлемгә ничек әзерләнүе аның үзеннән тора.

> *«Әгәр Раббың теләсә иде, әлбәттә, җир йөзендәге кешеләр барчалары иман китерер иделәр. Ә син, Мөхәммәд г-м, барча кешеләрне ышандыру өчен аларны көчләр идеңме?»* [10:99].

Ходай Тәгалә дингә пәйгамбәрләре аша өнди, ләкин ул дингә көчләми. Ул игелекле булу зарурлыгы турында бары тик кисәтә генә: *«Тәхкыйк Нухны каумена пәйгамбәр итеп җибәрдек, ул кауме эчендә аларны дингә өндәп тугыз йөз илле ел торды, кауме исә иман китермичә залим булдылар һәм аларны Туфан суы тотты»* [29:14]. Кешеләрне тәкъва итәр өчен Нухка мең ел вакыт та җитми һәм кешеләргә җәза бирелә. Алар коткарылмый, алар батырып үтерелә. Әйтелгән: *«Аларга пәйгамбәрләре могҗизалар вә ачык аңлатмалар белән килделәр, Аллаһ аларны золым итмәде, ләкин алар Аллаһыга каршы барып үзләренә золым иттеләр»* [30:9]. Ходай Тәгалә аларны коткара алмый, ләкин аларны батырганнан соң яңа буыннарны тудыра ала. *«Соңра алардан соң башка каумнәрне чыгардык»* [23:42]. Ходай Тәгалә кодрәтендә аларга җәза бирү, әмма аларны көчләп дингә китерү түгел. Ходай Тәгалә пәйгамбәрләр сайлап алып аларга хакыйкатьне ачкан. Калган нәрсәләрне ул һәркемнең үз ихтыярына калдырган.

Исламда мөселманнарны Аллаһыдан һәм Кыямәт көненнән куркырга тиешле Алла коллары дип атау кабул ителгән. Әйтелгән: *«Аллаһыдан куркыгыз, миңа итагать итегез»* [26:126]. «Кол» — «габд» *(`абд)* — һәм «куркыгыз» дигән сүзләр һәрбер сүрәдә диярлек очрыйлар. Ләкин аларны туры мәгънәдә аңларга тырышу берни дә бирми. Сукырларча табынуның мәгънәсе юк, сайлап алу хокукы кешенең үзенә бирелгән, ә иреклe ихтыяр һәм коллык — бервакытта да бергә сыеша алмый. Коллык ул кешенең ирегеn инкарь итә һәм аны көчләүне таный, әмма әйтелгән бит: *«Дингә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар. Ясалма, ялган, батыйль диннән Аллаһ төзегән хак дин ачык аерылды»* [2:256].

«Габд» (*`абд)* «кол» дип тәрҗемә ителә. Әмма фигыль төрле мәгънәгә ия. Гыйбадәт *(`ибадат)* — Ходайга хезмәт итү, шуңа күрә «габд» (*`абд)* «кол» түгел, ә Аллаһның «хезмәтчесе» мәгънәсенә ныграк туры килә. «Дини контекстта,— дип яза Сәед Мөхәммәд Нәкыйб әл-Әттас,— *`abd* термины үзенең Ходай алдындагы бурычының абсолютлыгын таныган хәлдә, моңа риза булып, үзен Аңа хезмәткә багышлаган кешене тасвирлый». «Ходайга хезмәт итү *(khidmah*) концепциясе,— дип дәвам итә ул,— үзенең хезмәтен тәкъдим итүченең, вассал түгел, ә «ирекле», «үзенә-үзе хуҗа» икәнлеген күз алдында тота». «Аллаһ колы» дигән сүз Коръәннең кешене ирекле итүгә юнәлдерелгән рухын бозып күрсәтә.

Иң мөһиме — курку түгел, сайлаган юлыңнан тайпылмыйча бару. «Аллаһтан куркыгыз» дип әйтү ул «аның каршында калтырап торыгыз» дигән сүз түгел, моның мәгънәсе башка — диндар булыгыз, игелекле булыгыз, яманлыктан ерак торыгыз, гөнаһлардан сакланыгыз дигәнне аңлата. Башкача әйтсәк, «куркыгыз» дигән сүзне минем арттан барыгыз, мине тыңлагыз, инаныгыз һәм дин тотыгыз дип аңларга кирәк. Һәм «кол» дигән сүзнең мәгънәсе башка контекстка ия, ул Аллаһның «дәвамчысы», үз хуҗасының артыннан ияреп баручы «хезмәтчесе» дигәнне аңлата, ул мәет юучылар кулындагы мәет тә, хуҗаның тимер кулындагы таяк та түгел.

Коръәннең мәгънәсе буенча, тәкъва кеше Аллаһның колы була алмый, чөнки аның сайлап алу хокукы булганлыктан, ул әлеге юлны үзе сайлап алган һәм ул аңлы рәвештә табына, бу эшкә хезмәт итә, ислам кануннарын үти. Ул Аллаһны чиктән тыш яратырга мөмкин, ләкин ул кол түгел. «Гыйбадәт,— дип яза Сәед Мөхәммәд Нәкыйб әл-Әттас,— аңлы рәвештә һәм теләп кылынган, бары тик Аллаһка гына багышланган, Аның тарафыннан хупланган хезмәт итү гамәлләрен, мәҗбүри табыну йолаларын аңлата». Гыйбадәт — ул хезмәт итүнең бар җыелмасын үз эченә алучы бик тирән мәгънәле термин, ә «үзенең ахыргы, иң югары стадиясендә гыйбадәт *(’ibadat) «*белем» — мәгърифәт *(ma`rifat)* мәгънәсенә ия була». Шул рәвешле, әлеге сүзне табыну йолаларына гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде.

Сәед Мөхәммәд Нәкыйб әл-Әттас дин кагыйдәләрен, йолаларын үтәү белән бәйле тышкы игелекне һәм «йөрәк хәрәкәтләренә бәйле» эчке, яшерен игелекне аерып күрсәтә. Биредә күңелгә шик төшә. Игелек тышкы һәм эчке була алмый, әйтик, кешеләр өчен — бер кыяфәттә, үзе өчен — икенче төрле. Йолаларны үтәү кешенең үзенә кирәк, алар дөньяны яхшыртмый, ә шәхеснең эчке халәтен үзгәртә: ул үзенең вазифа-

сын да, яхшылык белән яманлык арасыннан берсен сайлап алу зарурлыгын да ачыграк аңлый башлый, ә игелек исә җәмгыять тормышын яхшыртуга, халыкны үстерүгә, кешелекне коткаруга юнәлдерелә.

> *«Сезләрдән һәрбер җәмәгать өчен шәригать төзедек һәм диндә ачык юллар күрсәттек. Әгәр Аллаһ теләгән булса, әлбәттә, бөтен дөнья кешеләрен бер диндә, бер юлда һәммәсен бер җәмәгать кылыр иде, ләкин сезгә биргән нигъмәтләре һәм иңдергән Коръән хөкемнәре белән Аллаһ сезне сынап карарга теләде. Шулай булгач, алданмагыз, гөнаһлардан саклануда һәм савапны кәсеп итүдә ярышыгыз һәм ярышта алга чыгыгыз!!! Бит кайта торган җаегыз Аллаһ хозурында, анда сезгә Аллаһ дөньяда вакытларыгызда Аллаһ хөкемнәрендә ихтилаф кылышуларыгыз белән хәбәр бирер»* [5:48].

Ходай Тәгалә безнең барыбызның да кол булуын теләсә, төрле диннәр һәм халыклар булмас иде. Ислам — ирекле кеше дине, ул — азатлыкка юл. Бер үк вакытта кол да, мөселман да булу мөмкин түгел, бу — мәгънәсезлек. Җәннәттә күндәм ялчылар төркеменең керәге юк. Галәм иҗат кешеләренә мохтаҗ.

XX гасыр тормышка җитди үзгәрешләр кертте. Кешеләр милли киемне түгел, модалы һәм уңайлы киемне өстен күрәләр. Тормышның тышкы иҗтимагый нормалары эчке дәлилләргә алмашынды. Җәмәгать кеше алдында чигенеп куйды. Шәхес үзе җәмгыятькә тиңләште. Дин үзе дә чиркәү тамашасыннан, социаль феноменнан интим, рухи, бик шәхси нәрсәгә әверелә башлады. Кешеләр үз тормышларына тыгылганны һәм нәрсәнедер көчләп тагуны яратмыйлар, үзләре теләгәнчә сайлап алуны өстенрәк күрәләр.

Ислам — мәңгелек хәрәкәт, һәрдаим икеләнү һәм туктаусыз эзләнү ул. Катып калган, димәк, үлгән дигән сүз. Ислам баш өстендә эленеп торучы гильотина түгел, ул — моңарчы күрелмәгәнне эзләүгә этәргеч. Мөхәммәт Икбал әйткән: «Хәзерге заман мөселманы үз халәтенең кадерен белсен, үзенең иҗтимагый тормышын югары принциплар нигезендә үзгәртеп корсын һәм исламның моңарчы өлешчә генә ачылган максатыннан исламның олы максаты булган рухи демократияне үстереп җибәрсен иде».

Бидгать... Бу сүз авыздан бик җиңел очып чыга түгелме икән? Гадәти булмаган берәр нәрсә килеп чыкса, аңа шунда ук бидгать дигән ярлык тагалар. Кайбер сөнниләр өчен шигыйлар — диннән язган мөртәтләр, кайбер шигыйлар өчен, киресенчә, сөнниләр — диннән язучылар. Мондый мантыйкка иярсәң, тегеләрен дә, боларын да үлем җәзасына тартырга була, гәрчә бу хәл Коръәннең дин тоту ирекге турындагы аятьләренә каршы килсә дә.

Фән дөньясында бәхәсләр гадәти күренеш булып санала һәм хәтта бер-береңнең хатасы да хакыйкать эзләү кебек кабул ителә, ә исламда исә теләсә нинди яңа фикернең тыелуы мөмкин.

Идрис Шах болай дип яза: «Кеше йә дин тотучы, йә дин тотмаучы, йә, ихтимал, агностик булырга тиеш дип уйлыйлар һәм моны бик еш кына аксиома итеп саныйлар. Әгәр кеше дин тота икән, ул, үз фикеренчә, үз ихтыяҗларын канәгатьләндерә алучы динне яки системаны кемнеңдер күрсәтеп бирүен көтәчәк. Әмма бу ихтыяҗларның нидән гыйбарәт икәнен, ихтимал, үзенең дә аңлап җиткермәвен аның үзенә күрсәтеп бирүчеләр аз булыр».

Мәңгелек хакыйкатьләрне беләсе килә, әлбәттә, ләкин алар юк, күрәсең. Яхшылык һәм яманлык — катып калган категорияләр. Алтын кагыйдә бар: «Һәркем үз-үзен, башкаларның ничек булуын тели, шулай тотарга тиеш». Бу кагыйдә христианлыкта да, исламда да, конфуциячелектә дә бар. Кытайның бер акыл иясе моны Насретдин муллага әйткәч, мулла болай дип җавап биргән: «Бер кош үзенә бер дә зарары тими торган агулы җиләкләр ашап яши. Бервакыт ул бу җиләкләрне җыя да үзенең дусты атка ашата, шул рәвешле, иртәнге аш корбан китерүгә әйләнә». Урта гасырларда яхшы хезмәт иткән шәригать нормаларының XXI гасырга яраксыз булулары мөмкин.

> *«Вә дәлилең, белемең булмаган нәрсәгә иярмә»* [17:36].

Ислам үз заманы өчен дөньяга иң алга киткән караш булган. Ул ачыктан-ачык прогресс сыйфатында барлыкка килгән. Тәкъвалык илгә һәм халыкка өстенлек биргән, ул кешеләрне акыллы, булдыклы иткән, җәмгыятьтәге ызгыш-талашларны туктаткан. Ислам аркасында Көнчыгыш югары дәрәҗәдәге белем һәм зирәклек тупланышына әверелгән. Мөселманнар Мәккәгә карап дога гына кылмаганнар, Көнчыгыш культурасына йөз дә тотканнар.

Аннан соң мөселман дөньясы йокыга талган һәм хәзерге көнгәчә үзенең артта калганлыгын бетерә алмый. Самолетлар, автомобильләр, космик станцияләр, азмы-күпме җитди ачышлар Көнбатышта ясала. Сәйид Котб раславынча, «кешелек ялгыш юлдан бара». Ул болай дип яза: «Көнчыгыш цивилизациясенең рухи асылын аның барлык доктриналары һәм тәртипләре белән бергә тутык ашый бара... Матди җитештерү күләменең зурлыгына, фән һәм техниканың югары күтәрелүенә карамастан, аңа регресс һәм кырылып бетү

куркынычы яный». Ләкин күзгә ташланып торучы нәрсәләрне күрмәү мөмкин түгел. Көнбатышның өстенлеге кешелекнең иң югары казанышларын үзләштерүгә нигезләнгән. Чынлап та, дәвалаучы медицина, кешеләрне баетучы технологияләр, халыкны туендыручы һәм хәерчелекне бетерергә ярдәм итүче заманча агрокультура, тигезлеккә һәм гаделлеккә омтылу — Коръән өнди торган бар нәрсәләр нәкъ менә Көнбатышта гамәлгә ашырыла. Көнбатышның «наданлыгын» аңлатырга тырышып, Сәйид Котб болай дип яза: «Без самолетлар, ракеталар ясаган, атомны таркаткан, водород бомбасы уйлап тапкан, табигать законнарына төшенеп, аларны үзенең эшчәнлегендә файдаланучы акыл шулай ук кешелек тормышының строен, күзаллауларга һәм инандыру концепциясенә кагылышлы кагыйдәләрне, әхлак нигезләрен булдыру мәсьәләсен дә хәл итәргә сәләтле дип хыялга китерәбез». Югары үсешкә ирешкән җәмгыять строе, аңа тәңгәл әхлак, хезмәт күнекмәләре булдырмыйча самолетлар һәм ракеталар төзеп булмый. Башкача фикерләү — үз-үзеңне алдау ул.

Бөек Низами болай дип язган: «Юлда йокыга киткән кеше йә бүреген, йә башын югалтыр».

Гарәп илләре колониаль бәйлелектә булган чакта барысына да дөнья империализмын гаепләргә була иде, әмма аннан соң да үз юлыңны сайлар өчен җитәрлек вакыт узды инде. Мөселман илләренең үсеш модельләре әллә ни искитәрлек түгел. Иранда, Пакистанда «саф ислам» илләре төзергә тырышу исә аларны тагын да артта калуга, сәяси тотрыксызлыкка, эчке сугышларга һәм ислам дәүләтләре арасында сугышларга китерде. Хәзер инде артта калу сәбәпләрен тыштан түгел, эчтән эзләргә кирәк.

Инде ихластан танырга кирәк — ислам дөньясы нигездә чимал белән сәүдә итә һәм көнбатыш товарлары сатып ала. Анда фәннәр һәм технологияләр үсми. Ислам дөньясы кешелек үсешенең төп юлларыннан читтә калды.

Артта калганлыкны тәкъвалык белән акларга ярамый. Әгәр мөселманнар тәкъва икән, алар нигә артта калганнар соң? Коръәннең вазифасы башка — мөселманнарны планетада иң алга киткән кешеләр итү иде.

Пәйгамбәрнең фикердәшләре исә һәрбер галим Коръәнне мөстәкыйль өйрәнә һәм үз фикерен — иҗтиһадны булдыра ала дип санаганнар. Яшь ислам гамәли проблемаларга җавап биргән. Гарәпләр Борынгы Грециядән башлап төрле культураларның казанышларын үзләренә йотлыгып сеңдергәннәр. Хәлифләр борынгы яһүдләрнең, византиялеләрнең, фарсыларның, шулай ук грекларның һәм буддачыларның җирләренә хуҗа булганнар, яулап алу походлары белән Франциянең көньягына, Испаниягә, Һинд үзәннәренә кадәр барып җиткәннәр. Ислам башка традицияләргә ачык булган. Аның өстенлеге дә шунда булган. Фикер хөрлеге һәм ачыклык исламны көчле иткәннәр. Европа гарәп фикер ияләреннән күп нәрсәгә өйрәнгән. Әбүгалисинаның «Әл-Канун» дигән медицина трактатыннан Европада XVII гасырга кадәр файдаланганнар. Европа ибн Рушдины йотлыгып укыган, ә әл-Хәрәзми язмалары аша гарәп цифрлары һәм алгебра (әл-җабр) белән танышкан. «Әл-Хәрәзми» дигән ялгызлык исем «алгоритм» дигән терминга әйләнгән. Ислам идеяләре Европада XII гасырдан алып XVI гасыр ахырына кадәр өстенлек иткәннәр. Евгений Бертельс болай дип язган: «Европа культурасы тарихында IX — XIII гасырлар чоры бик каты төшенкелек вакыты икәнен искә төшерсәк, Европа халыкларын тупиктан чыгарып алга таба үсү юлын нәкъ менә көнчыгыш философларының хезмәтләре күрсәткән дигән нәтиҗәгә килмичә мөмкин түгел». Әмма шуннан соң ислам фикере схоластикага чумган һәм шуннан чыга алмый, күрәсең.

Тәкъвалык һәм артта калганлык бер-берсе белән сыеша алмый. Әгәр синең халкың алга бармый икән, әгәр мөселман дөньясы христиан дөньясыннан артта кала икән, тәкъвалыкның мәгънәсе нидә? Фәхеш йортлары булмауда һәм шәраб эчмәүдәме? Шәраб эчүне һәм комарлы уеннарны тыю халык алга китсен өчен кертелгән ләбаса!

Культураның узган замандагы бөеклеге XXI гасыр өчен дәлил була алмый. Узган заманга сокланып, үз-үзеңне юатып утырырга ярамый. Бүген телефон һәм компьютер кулланалар, самолетларда очалар, ә гарәпнең чабыш атларына ипподромнарда гына сокланалар. Көнчыгышның бөтен культурасы, саф токымлы гарәп аты сыман, хуҗалык өчен файдасы аз нәрсә соклану предметы гына булып калды. Ул күбрәк ачык һавадагы тере музейга охшап бара. Ислам хәлифәтләре дәверен Ататөрек бетермәде, ислам дөньясын традицияләргә сукырларча ияреп бару (тәкълид) какшатты.

Дин галимнәре исламны яңартудан куркалар, динне юкка чыгарачак дип санап, рациональлектән куркалар. Сәйд Мөхәммәт Нәкыйб әл-Әттас танып белүнең иң югары формасы итеп тоемлауны (интуиция) саный. «Кеше аңының иң югары баскычында пәйгамбәрләр һәм изгеләр ирешә торган тоемлау дәрәҗәсе чынбарлык табигатенең тирән катламнарын күрергә мөмкинлек бирә». Автор, җәмгыять күбесенчә надан булганлыктан, исламны тоемлау нигезендә шәрехләү — сайлап алынганнар, изгеләр тәкъдире һәм гади кешеләргә берничек тә рөхсәт ителми торган гамәл дип саный. Шунысын истә тоту зарур: пәйгамбәр халыктан бер дә читләшмәгән, киресенчә, ярлылар һәм эзәрлекләнүчеләр белән теләп аралашкан. Бүген исә сәедләр халык төркеменнән өстәрәк торуны мәгъкульрәк күрәләр һәм яңа пәйгамбәрләр роленә диярлек дәгъва кылалар.

Йосыф әл-Кардави, үзе ижтиһадка өнди, үзе болай дип яза: «Теләгән һәркем ижтиһадка катнаша ала торган вазгыятьне шул хәлендә калдырырга ярамый, чөнки бу анархиягә һәм гыйсъянга китерәчәк». Ул ижтиһадка лаеклылар һәм лаеклы булмаганнар бар дип саный. Лаеклылар төркемен кем билгеләр икән соң?

Дин галимнәре исә урта гасырларда ижтиһадка хокукы булган кешеләр төркемен чикләгән күренекле акыл ияләренә таяналар. Бусы аңлатырлык хәл. Ул заманда халыкның белем дәрәҗәсе шундый булган: дини темаларга фикер йөртүне бар кеше дә булдыра алмаган. Бүген исә бар кешенең дә белеме һәм югары белем алу мөмкинлеге булу вазгыятьне үзгәртте. Һәркем Коръәнне мөстәкыйль рәвештә, хәтта ана телендә өйрәнә ала.

Йосыф әл-Кардави ижтиһадка башка төр чикләнмәләр дә куя: «Мөселманнар өчен уразаның мәҗбүрилеге, шәраб эчүне яки дуңгыз ите ашауны тыю, рибачылыкны тыю яки караклыгында бернинди дә шик булмаган очракта каракның кулларын кисү бурычы… кебек катгый мәсьәләләрдә ижтиһадка урын юк. Шулай ук мәрхүм атаның балалары арасында мирас бүлешү, өстәвенә аның улларына кызларына караганда ике тапкыр күбрәк мал тияргә тиеш кебек мәсьәләләр һәм Коръәннең һәм чын Сөннәтнең бөтен Өммәт тарафыннан кабул ителгән башка кагыйдәләре Өммәтнең идея һәм иҗтимагый бердәмлегенә терәк булган дини догмалар булып торалар да инде». Коръәндә тыелган нәрсәләргә карата бик зирәк формула бирелгән аятьләрне табарга мөмкин. Әйтелгән: *«Иман китереп, изге гамәлләр кылып, мөселман булган кешеләргә әүвәлдә эчкәннәре өчен гөнаһ юк, әгәр яңадан эчүдән саклансалар, иманнарын куәтләп изге гамәлләр кылсалар, соңра саклансалар, янә иманнарын тазартып тәкъвалык кылсалар һәм изге гамәлләрне — яхшы эшләрне эшләсәләр. Бит Аллаһ яхшы эшне кылучыларны сөя»* [5:93]. Мондый аятьләр заманча шәрехләүгә мохтаҗ.

Коръәндә кяферләрне үтерү турында күп аятьләр табарга була. Әйтелгән: *«Әгәр сугыш хәрам булган айлар үтеп китсә, мөшрикләрне кайда тапсагыз, шунда үтерегез...»* [9:5]. Әйтергә кирәк, кайбер дин галимнәре тарихи шәригатьне үтәмәгән барлык кешеләрне дә мәҗүсиләр дип аңлыйлар. Сәйид Котб яза: «Аллаһ сызган юлга тәңгәл яшәүче кешеләр — мөселманнар, ә теләсә нинди башка юлдан баручылар — мәҗүсиләр, аларны бу дин танымый». Коръәндә исә христианнар һәм иудейлар турында, алар мәҗүсиләр түгел, алар «китап бирелгән кешеләр» дип әйтелгән.

Алга таба мондый аятьләр табарга мөмкин: *«Аллаһыга вә ахирәт көненә иман китермәгән кешеләр белән сугышыгыз вә Аллаһ һәм Аның рәсүле хәрам кылган нәрсәләрнең хәрамлыгына ышанмаган вә хак дин — исламны дин итеп алмаган кешеләр белән сугышыгыз! Алар китап бирелгән кешеләрдер, кимсетелгән хәлдә үз куллары белән җәза-түләү биргәнчегә чаклы алар белән сугышыгыз!»* [9:29]. Шул ук вакытта башка бер аять ул кадәр үк катгый түгел: *«Раббыңның юлы булган ислам диненә кешеләрне чакыр, вә чакырыгыз Коръән дәлилләре белән, дәхи тәэсирле яхшы вәгазьләр белән, дәхи кешеләргә хаклыкны төшендерү өчен алар белән тартыш вә көрәш иң күркәм юл белән!»* [16:125].

Пәйгамбәргә әйтелгән: *«Ий Мөхәммәд г-м! Кяферләр һәм монафикълар белән сугыш кыл вә аларга катылык, гайрәт күрсәт!»* [9:73]. Ә пәйгамбәр үзе болай дигән: «Дөрестән дә, Аллаһ игелеклелек, бар гамәлләрдә дә йомшак мөгамәлә ярата». Без бер үк мәсьәләгә карата төрле күрсәтмәләр күрәбез. Яки әйтелгән: *«Ий мөэминнәр! Үзегезгә якын кяферләр белән сугыш кылыгыз! Алар сездә куәт вә катылыкны тапсыннар өчен...»* [9:123]. Әмма пәйгамбәр: «Диндә чамасызлыктан сакланыгыз», — дип кабатларга яраткан. Мәзһәбләр бу кагыйдәләрне катгый дип шәрехлиләр. Бүген мондый катгыйлык үз-үзен берничек тә акламый.

*«Әгәр Аллаһ теләсә ки, бөтен дөнья кешеләрен һидәяткә салыр иде...»* [13:31].

XVIII һәм XIX гасырлар чигендә татарлар арасында җәдидчелек хәрәкәтен башлап җибәргән Габденнасыйр Курсави халыкларга: «Сез хак вә тәкъва мөселманнар түгел. Сез Аллаһының Коръәненнән һәм пәйгамбәрнең сүзләреннән читкә тайпылдыгыз»,— дигән өндәмә белән мөрәҗәгать итә. Ул Изге китапның үзен укырга һәм гамәлдәге традицияләрне тәнкыйди бәяләргә чакыра.

Бохарада булган вакытта ул Ходайның сыйфатлары турында фикерен белдерә. Ул чакта дин галимнәренең бер төркеме Ходайның сыйфатлары — җиде, ә икенче төркеме — сигез дип исәпли. Курсави раславынча, җиде дип тә, сигез дип тә әйтеп булмый, чөнки Коръән сыйфатлар санын берничек тә билгеләми. Әлеге мәсьәлә буенча Бохара әмире катнашында уздырылган голәмалар мәҗлесе фәтва чыгара, аның буенча Ходайның җиде яки сигез сыйфатын танымаган теләсә нинди мөселман мөртәт дип санала һәм аңа үлем җәзасы бирелергә тиеш була. Курсавины төрмәгә ябалар, әмма аңа үлем җәзасы бирелми кала — аны элеккеге остазы, бик абруйлы шәех Ниязкули яклап чыга. Курсавины үзенең сүзләреннән ваз кичәргә мәҗбүр итәләр һәм аның хезмәтләрен халык алдында яндыралар. Шуннан соң ул Бохарадан туган иленә кача.

*«Әгәр сине ялганчы дисәләр, бу кяферләрдән элек Нух кауме Нухны ялганчы диделәр, вә Гад кауме Гадны, Сәмуд кауме Сәмудны ялганчы диделәр. Намруд кауме Ибраһимны, Лут кауме Лутны, Мәдийән кауме Шөгәебне ялганчы диделәр, вә Муса да ялганга тотылды»* [22:42—44].

Курсави яшәгән елларда Бохараның коллар базары Иран шигыйлары белән тулган була. Традиция буенча алар кяферләр булып саналганнар, шуңа күрә «көлли мөслим хөрр» (һәр мөселман ирекле) дигән принцип аларга кагылмаган. Ләкин Коръәндә дә, Сөннәттә дә кяферлекнең төгәл аңлатмасы юк. Әгәр алар моңа хаклары булмаган килеш башкаларны кяферлектә гаеплиләр икән, алар бер-берсеннән ни белән яхшы? «Аларның мәзһәбе, сезнеке кебек үк — һәвәслек (һава) ... Сезнең сыеныр урыныгыз — Аллаһ җитәкчелеге һәм Сөннәт юлыннан бару», — дип язган Курсави.

Коръәнгә һәм Сөннәткә мөрәҗәгать итү чынлыкта теләсә нинди мәзһәбне инкарь итә. Замандашлар күз алдында тәкълид котылу ысулы булмаган, мөстәкыйль эзләнү — иҗтиһад кирәк булган. Биредә Курсави өчен җәмәгатьчелек фикере хакыйкать билгесе булып тормаган. Аныңча, үз фикерләренең хаклыгына, аларның «тугры юлга» тәңгәллегенә инанган галим үзе үк җәмәгать (мөселманнар җәмгыяте) булып санала ала, шуңа күрә ул, хәтта үз гамәле күпчелек тарафыннан хөкем ителсә дә, үз ихтыяры буенча эш итәргә хаклы. Хакыйкатьне яклаган кеше җәмгыять белән тигез дәрәҗәдә бөеклеккә ия. Бу — теологиядә революция булган. Курсави идеяләрен татар дин галимнәренең иң яхшы төркеме күтәреп алган.

Курсавиның беренче тәнкыйди фикерләре барлыкка килгәннән бирле инде ике гасыр вакыт узган, әмма ул күтәргән проблемалар тирәсендәге бәхәсләр һаман дәвам итә. Хәйдәр Баш болай дип яза: «Мәзһәбләр һәм мәшрәбләр принципларын кире кагып, турыдан-туры Коръәнгә һәм Сөннәткә, Сәгадәт Гасыр дәверенә мөрәҗәгать итәргә өндәү үзе үк Коръән һәм Сөннәт тарафыннан билгеләнүче иҗма-и өммәтне һәм кыяс-и фикъһене инкарь итүне аңлата... Ә Әхл әс-Сөннәт мәзһәбләре һәм мәшрәбләре барлык дини проблемаларга иң дөрес принциплар нигезендә анализны күптән ясадылар бит инде». Вакыт туктап калган да, шуңа күрә барлык проблемаларны да хәл ителгән дип санарга була диярсең... Хәйдәр Баш дәвам итә: «Өммәтнең гасырлар буе бернинди шик-шөбһәсез мәзһәбләргә һәм мәшрәбләргә таянып эш итүе, мәзһәбләр һәм мәшрәбләр имамнарының гасырлар буе бәхәссез авторитетлар булып калуы — мәзһәбләр һәм мәшрәбләр карашының төпле булуын һәм һәрвакыт хакыйкатьне чагылдыруын тарихи дәлилләп тора». Әгәр дә кешелек шушындый ук мантыйкта фикерләсә, кояш системасының төзелеше хәзергә кадәр Коперник буенча түгел, Птолемей буенча аңлатылыр иде.

Мәзһәбләрне, һәм тулаем тәкълид принцибын, шулай ук иҗмагъны ялкынланып яклау астында бер гади фикер ята — теләсә нинди мөселман уйламый-нитми үз остазы артыннан барырга тиеш. «Хакыйкать җиңсен өчен, дин тотучылар күндәм булырга, үз тирәлекләрендәге абруйлы үзәккә итагать күрсәтергә тиешләр. Бу күндәмлек (итагать) — Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның Илчесенә күндәмлекнең (итагатьнең) бер өлеше...». Абруйлы үзәкнең Ходайны һәм Аның пәйгамбәрен вәкиллек итү функциясен үз өстенә алырга ни хакы бар?! Фәрит Исак дөрес яза: «Исламда демократиянең булуы мөмкин түгел, бөтен хакимият — Ходайдан дигән идеяне яклап, үзләрен Ходай вәкилләре югарылыгына күтәреп, калганнарны гади башкаручылар дәрәҗәсенә төшергән кайбер дин лидерларының демагогик сафсатасыннан башлары әйләнгән кешеләрне дә телгә алып үтәргә кирәк»,— дип яза ул. Һәркемнең хакыйкатькә үз юлы бар, бу юлны бернинди остаз да, имам да алыштыра алмый. Дин хезмәтчеләре, үзләре дә тәкълид тозагында булмаган очракта, хакыйкатьне эзләргә ярдәм итә алалар.

Мөхәммәд пәйгамбәр әйткән: «Хактыр, Аллаһ һәрбер йөзьеллык башланганда өммәткә динне яңартучы кеше җибәреп торыр». Пәйгамбәр дин яңарту астында нәрсә күздә тоткан соң? Коръәнне шәрехләүнең үз заманына һәм билгеле шартларга туры килергә тиешлеген, күрәсең. Ислам — дөньяга караш, ул һәрдаим үсештә. Аның көче шунда. Коръәнне сүзгә-сүз уку аның мәгънәсен төгәл бирә алмый, чөнки аның принциплары шушы урында, шушы заманда шушы кешеләр өчен яраклы булырга тиеш. Вакытлар узган саен, нормалар үзгәрә, ләкин Коръәннең рухы үзгәрми. Габдулла Буби болай дип язган: «Әгәр дә без гел иске тәфсирләргә генә мөрәҗәгать итсәк, бу Коръәннең чиклелеген һәм бетүен, ә пәйгамбәр сүзләренең ялганлыгын аңлатыр иде». Чыннан да, хәтта бик абруйлы булсалар да, аерым кешеләрнең сүзе Коръәннән өстен була алмый. Хакыйкатькә дәгъва кылырга беркемнең дә хакы юк, хакыйкатьне танып белүгә юл гына күрсәтергә мөмкин.

Габдулла Буби, мәзһәбләрнең чамадан тыш табынуы «ислам халыкларының ләгънәтенә» әйләнде дип әйткән. Ә бит мәзһәбләргә нигез салучылар үзләре мөселманнарны төрле мәктәпләргә бүләргә уйламаганнар да. Әбү Хәнифә кисәткән: «Минем дәлилләремне белмәгән кешеләргә минем сүзләремә таянып, карарлар — фәтвалар чыгару тыела». Ул үзенең урынын һәм вазифасын яхшы аңлаган, ләкин аның дәвамчылары үз остазларын аңламаганнар.

Без татарларларны хәнифи агым мөселманнары дип кабатлыйбыз. Бу сүзләрнең мәгънәсе нидә? Әбү Хәнифәгә ияреп, йөклелекнең вакыты ике ел дип санавыбыздамы? Яки хакыйкатькә бердәнбер юл тапканбызмы? Әллә без Коръәнне иң дөрес шәрехләүчеләрме? Бәлки, без дөньяви дәүләттә мөмкин булмаган тарихи шәригать кертергә телибездер? Нindидер мәзһәбкә иярү, турысын гына әйткәндә — Коръәнне кысага кертү дигән сүз ул. Әмма барлык мәзһәбләрне бергә алып карасаң да, Изге китап алардан киңрәк, тирәнрәк. Һәм һәрбер яңа буын аннан яңа фикерләр ала. Әлеге процесс Коръәннең мәңгелек зирәклеге кебек үк чиксез.

Бөек Сәгъди сораган: «Йокыдагы кеше үзе шикелле башка бер йоклаучыны ничек уята ала?»

Исламның татар халкын саклап калудагы роле чагыштыргысыз зур. Христианлаштыру чорында тел, культура һәм дин халыкны ассимиляциядән саклап калганнар. Ислам татарларны җәмгыятьләргә берләштереп үзара ярдәмләшү механизмы булдырган. Ул, традицияләрне туплап «катырып» куеп, этник үзенчәлекләрне саклаган. Әмма XIX гасырда безнең халык алдына башка бурыч килеп баса: сакланып калу түгел, үсешкә ирешү. Туплап «катырып» саклау бу мәсьәләне инде хәл итә алмый, киресенчә, киртәгә әверелә һәм мондый хәлдән чыгу юлын табуда җәдидчелек ярдәмгә килә.

Җәдидчелек хәрәкәте чагыштырмача артта калган Көнчыгышны тиз үсә торган Көнбатыш белән чагыштырудан килеп чыккан. Җәдидчеләр үсешнең төп юлын заманча белем алуда һәм башка халыкларның культура казанышлары өчен ачык булуда күргәннәр, алар Европадан өйрәнергә өндәгәннәр. Татарларның иң яхшы мәдрәсәләре җәдид мәдрәсәләре булган.Татарның XIX — XX гасырдагы күренекле фикер ияләре, язучылары, җәмәгать эшлеклеләре нәкъ менә шул тирәлектән чыкканнар.

XX гасыр башына кадәр татарлар өчен күп кенә һөнәрләргә, дөньяви университетлар оештыруга һәм икътисади эшчәнлеккә чикләүләр яшәп килгән. Православиелеләр ачыктан-ачык өстенлекләрдән файдаланганнар. Шуңа да карамастан исламны яңарту аркасында татарлар конкурентлыкка сәләтле булганнар һәм культура өлкәсендә бик зур сикереш ясаганнар. Татарларны традицияләрне «катырып» саклап кую түгел, ә нәкъ менә исламны яңарту ныгыткан.

Гасырлар буе торгынлык кичергән Көнчыгышка җәдидчелек идеяләрен кабул итү катлаулы булган. Муса Бигиевнең хезмәтләре госман мөселманнары башлыгы тарафыннан сафсата дип аталган. Муса Бигиев Советлар Русиясеннән качып китәргә мәҗбүр булган.

> *«Әгәр бер шәһәр халкына газап белән куркытучы пәйгамбәр җибәрсәк, ул шәһәрнең нигъмәт эчендә булган хуҗалары, без сез китергән дингә ышанмыйбыз, дип җавап бирделәр»* [34:34].

Мөхәммәд пәйгамбәр заманыннан соң күп нәрсәләр үзгәргән. Бик тиз үсүче фәнни мәктәпләр, заманча технологияләр һәм техника искергән традицияләргә урын калдырмыйлар. Кайвакыт дин һәм фән параллель рәвештә яши яки фән динне кысрыклый сыман тоела. Чынлыкта исә фәнни фикерләү исламга каршы тормый, чөнки ислам ул — бер үк вакытта ышану да, белем дә, боларның икесен дә үз эченә алучы культура. Мөхәммәд пәйгамбәр: «Кем башкаларны өйрәтү максатында күпме булса да фән өйрәнә — шуңа Аллаһы Тәгалә җитмеш изгенең котылу чарасын бирер»,— дип киңәш иткән. Димәк, фәннәр исламның табигый өлешен тәшкил итә.

Кайбер дин белгечләре Коръәннән иң яңа фәнни ачышларга дәлилләр эзлиләр. Дөрестән дә, анда Галәмнең киңәюе теориясен яки атомның бүленешен раслаучы юллар бар, ләкин Коръән конкрет белем энциклопедиясе түгел, ул иң яңа ачышлар каршында «аклану»га мохтаҗ түгел. Галәмнең төзелеше яки кеше эволюциясе мәсьәләләрендә Коръәнгә йөз тоту сәер булыр иде. Анда иң гомуми һәм якынча мәгълүматлар бирелгән. Фәннең вазифасы да Галәмнең тулы картинасын ачыклаудан гыйбарәт.

Хак мөселман — ул фәннәрне ихтирам итүче, фәннәргә төшенүче, белемле кеше. Мөхәммәд пәйгамбәр әйткән: «Белем алу — мөселманның иң төп бурычы». Бу — катгый таләп. Үз-үзеңне, тирә-ягыңдагы дөньяны, Галәмне танып белергә омтылу — хакыйкатьне, димәк, Аллаһы Тәгаләнең үзен аңлау дигән сүз. Әйтелгән: *«...Вә тәхкыйк Аллаһының һәрнәрсәне белем белән әйләндереп алганлыгын белүегез өчен»* [65:12]. Ул барысын да үз эченә ала, чөнки Ул — Галәмнең үзе. Теләсә нинди фән, теләсә нинди белем — Аллаһка таба бер адым, ул сукырларча табынуны түгел, кеше эшчәнлегенең файдасын көтә. Аллаһ җитмеш изгедән дә өстен күрсен өчен, җәмгыять файдасына тотылган аз гына белем дә җитә. Пәйгамбәр шулай дип әйткән.

> *«Аллаһ җирдәге, вә күкләрдәге яшерен нәрсәләрне һичшиксез беләдер»* [49:18].

Дин тотучыларның кайберләре могҗиза һәм күрәзәчелек таләп итә, ә дин белгечләре Коръәннән һәм пәйгамбәр тормышыннан моңа дәлилләр эзли. Ләкин могҗиза — бала-чагалар һәм беркатлы кешеләр өчен

уенчык ул. Табигать — үзе могҗиза. Могҗиза Җирнең тарту көчен җиңеп Галәмгә очкан кешенең мөмкинлекләрендә. Табибларның кешене клиник үлемнән соң терелтергә өйрәнүләре — могҗиза.

Ватиканда булган чакта миңа Татарстан мөфтие белән сөйләшеп алырга кирәк булды һәм мин аңа үземнең кәрәзле телефонымнан шалтыраттым. Ул бу вакытта Җиддәдә булып чыкты. Без бер-беребездән меңнәрләгән чакрым ераклыкта торып та сөйләшә алдык. Җирнең ясалма иярченнәре кешелекне элемтә пәрәвезе белән берләштерәләр. Күп гасырлар буена кешеләр үзара элемтә чаралары булдыруга ирешкәннәр — почта, фельдъегерь элемтәсенә меңләгән атчабарлар хезмәт иткән, аннан соң автомобильләр, самолетлар барлыкка килгән, ниһаять, телеграф, чыбыксыз элемтә уйлап табылган. Бүген исә электрон һәм мобиль элемтә системасы чып-чын могҗиза кебек, ә спутниклар бик биектә планета гакылының нерв җепселләрен тотып торучы фәрештәләр кебек тоела.

Наданлык могҗиза таләп итә, ә белем моңа мохтаҗ түгел. Белем могҗизаны үзе тудыра. Кеше даһилыгы бары тик бер буын эчендә генә, без яшь чакта фантастик романнардан гына укып белгән техниканы һәм технологияне тудырды. Аңлатып булмый һәм безнең акыл чикләренә сыймый торган нәрсәне эзләргә кирәк микән? Аңлатып булмый торган нәрсәгә ышанырга кирәк микән соң? Киресенчә, табигатьтә, ихтимал, чиксезлектән башка, бар нәрсәнең дә аңлатмасы табылырга тиешлегенә ышанырга кирәк.

Цивилизациягә ирешкән бар дөнья мәгариф мәсьәләләрен сүздә генә түгел, гамәлдә дә иң беренче урынга куйды. Алга киткән илләр бюджетында чыгымнарның беренче маддәсе мәгарифкә бирелгән. Бәлки, хак мөселманнар Суданда түгел, әнә шул илләрдә яшидер? Пәйгамбәр әйткән: «Бөтен нәрсәгә дә аерым юл бар. Җәннәткә юлны исә гыйлем ача».

Дөнья ашкынып үзгәрә. Көнчыгыш, Европаны һәм Американы сүгеп, үзенең вазифасы турында уйланып торганда, Көнбатыш үсеш юлыннан алгарак китә бара.

Кайда безнең кыйбла?

Көнбатыш чамадан тыш рациональ, артык индивидуальләшкән — Көнчыгыш шулай дип саный. Моңа үпкә белдерергә ярамый, бу — объектив вазгыять. Заман таләбе шундый. Конкуренция исә алга киткән, аңлы, киң белемле шәхесләр тәрбияләүне таләп итә. Масса яки коллектив белән ниндидер күренекле уңышка ирешү кыен.

XXI гасырны XX гасырдан аерып торучы нәрсә — мәгълүмат өстенлеге. Форд уйлап тапкан конвейер XX гасыр символы булса, яңа дәвернең символы — компьютер, Интернет һәм элемтәнең яңа технологияләре. Белем исә җитештерү ресурсларының иң мөһименә әверелде. Моның белән бергә кешенең роле дә үзгәрә, аның өчен иң мөһиме — иҗади фикерләү.

Ислам реформаторларының берсе Гамәл әд-Дин әл-Әфгани «интеллект һәм культураны рациональлек һәм дөньяви кыйммәтләрдән саклап калып, замана цивилизациясенең технологияләрен һәм эш коралларын үзләштерергә кирәк» дигән фикергә инанган булган. Кулланучы күзлегеннән караганда, әлеге принципка иярергә мөмкин, ләкин техниканы һәм технологияне үстерергә тырышсаң, рациональлектән башка берни эшли алмыйсың.

Көнбатышның характеры фәнни-техник прогресс һәм иҗтимагый тормышның алга киткәнлеге белән билгеләнә. Индивидуальлеккә бергәлекне һәм коллективны каршы кую, рациональлекне инкарь итү — үзеңне артта калуга күрәләтә дучар итү дигән сүз.

Җәмгыятьтәге йогынтысын саклап калырга теләсә, ислам заман таләпләренә җавап бирә белергә тиеш. Хикмәт Көнчыгышка арка белән борылып, Көнбатышка йөз тотуда түгел, ә дөньядагы барлык әһәмиятле нәрсәләрне үзләштерүдә. Инде бүгенге көндә АКШ, Европа һәм Көньяк-Көнчыгыш илләре бик тиз үсәләр икән, димәк, алардан өйрәнергә кирәк. Белем алырга шунда барырга кирәк.

Мөселман илләрендә күпләр Көнбатыш үрнәкләрен үзләренә турыдан-туры күчерә башладылар. Муса Бигиев моны «яңа тәкълид» дип атаган. Ул болай дип язган: «Мәзһәбләрнең берсен «ихтирам итү» турында фантазияләргә ярарга тырышып исламны һәм шәригатьне аларга корбан итү берничек тә риза булырлык нәрсә түгел. Хәтта моннан да зуррак һәм аңыбызны зарарлаган тагын бер кимчелегебез — хурлыклы һәм кимсеткеч неотәкълид. Традицион тәкълид шәригатьне мәзһәбләр изгелегенә табыну юлы белән корбан итүдән гыйбарәт булса, искә алынган заманча тәкълид исә Көнбатыш цивилизациясенә һәм аның сәяси казанышларына сокланудан килеп чыккан кимсенү җирлегендә исламнан баш тарту һәм мөселман өммәтен корбан итү булып тора».

Көнбатышны Көнчыгышка күчерә алмыйсың. Анда җирлек башка. Көнчыгыш либеральлекне чиста рәвештә кабул итми. Ул аны үз традицияләре аркылы үткәрергә тиеш. Тәкълид Көнчыгышныкы булса да, Көнбатышныкы булса да — яраксыз, чөнки ул исламның рухына каршы килә, ә Көнчыгышны Көнбатышка либераль фикер йөртүнең башлангычы булган иҗтиһад якынайта. Әгәр дә ирекле шәхес белемгә һәм фәнгә тартыла, прогресска омтыла икән, бу — көнбатыш культурасына да, ислам культурасына да яраклы.

*«Ул үлемне һәм тереклекне халык кылды, йөкләмәләр йөкләп сезне сынамак өчен, кайсыларыгыз яхшырак гамәлле икәнлеген белмәк өчен...»* [67:2].

Мөселманнар һәрбер эшне: «Бисмиллаһи-рахманир-рахим» (мәрхәмәтле һәм рәхимле Алла исеме белән) дип башлый. Бу нәрсәне аңлата? Аңа омтылырга, аның өчен яшәргә дигәннеме? Гади сорау, әмма аңа җавап бирү катлаулы... Әйтелгән: *«Без җирне һәм күкләрне, вә аларның арасында булган нәрсәләрне уйнапшаярып бушка гына халык кылмадык... Зекер ителгәннәрне һәммәсен фәкать хаклык илә халык кылдык, ләкин имансызлар Безнең хак эшебезне белмиләр»* [44:38—39]. Табигый законнар буенча яшәүче һәм мәгънәгә ия Галәм үзе хакыйкать булып тора да инде. *«Ул — Коръән, барча Галәм халыкларына вәгазьдер, кирәк эшләрне исләренә төшерүчедер, вә кешеләргә иманны, динне, һидәятне һәм тәрбияне кәсеп итә торган иң туры юлдыр. Сезләрдән туры юлга күнелергә теләге булган кешеләргә вәгазь һәм туры юлдыр. Юк, туры юлга күнелүне тели алмассыз, мәгәр барча галәмнәрне тәрбия итүче Аллаһы Тәгалә теләсә генә»* [81:27—29]. Коръән «бөтен дөнья кешеләре өчен вәгазь» [6:90], Җирдә яшәүчеләргә алдан искәртү, ә Галәмнең Алласы — яшәү мәгънәсе, башкача әйткәндә, матдәнең рухы, Галәмнең тәүге һәм ахыргы мәгънәсе, ул бар нәрсәне тәртипкә салучы, пространство һәм вакыт чиксезлеген кысаларга кертүче. Бу мәгънә «Китаплар анасында» буыннар тәҗрибәсе, кешелек тарафыннан даими тулыландырылып торучы галәми акыл сыйфатында туплана. «Китаплар анасы» — үлемсезлек сере.

Сәид Мөхәммәт Нәкыйб әл-Әттас: «Үзенең табигате (*fitrah)* буенча баштан ук камил булганлыктан, дөнья үсә-үзгәрә алмый»,— дип саный. Ул «Аллаһ аңында үзгәрмәс нигезләр сыйфатында» яшәүче «идеаль чынбарлык дөньясы» дигән төшенчәгә таяна. Болай шәрехләгәндә дөнья үз камиллегеннән ялтырап катып калган кебек күзаллана. Әмма биредә автор Алланы миф яки символ дип түгел, чынбарлык дип атый. Вакытлар узу белән үзгәрми торган чынбарлыкны тану кыен. Мөселман берлегенең башта Мәдинә белән чикләнеп, алга таба Гарәбстанга кадәр киңәюен, ә Мөхәммәд үлгәннән соң исламның кыска гына вакыт эчендә дөньяның дистәләгән зур илләрен үз эченә алуын искә төшерү дә җитә. Ислам дөнья күренешен үзгәртте. Кешелек тарихында бары тик Чыңгыз ханның Азиядән Европага ыргылышы гына ислам хәрәкәтеннән тизрәк һәм күләмлерәк булгандыр.

Ходай Тәгалә — үзен Галәмдә чагылдыручы чынбарлык. Әйтелгән: *«Кояш, Ай вә йолдызлар Аллаһ әмере буенча йөриләр, әгаһ булыгыз! Халык кылмак, һәр эшкә әмер бирмәк Аллаһ эше түгелме? Барча Галәмне тәрбия итүче Аллаһ бәрәкәт иясе булды»* [7:54]. Ул җирдәге тормышта, һәм, әлбәттә, кешенең үзендә гәүдәләнә. Пәйгамбәр әйткән: «Үз-үзен танып белгән кеше, үзенең Аллаһын да танып белгән». Болар барысы да — һәрдаим үзгәрештә һәм үсештә булган билгеләр. Мөхәммәт Икбал бик дөрес яза: «Коръән буенча дөнья үсешкә дучар ителгән. Бу — үсә торган дөнья. Ул күп гасырлар элек Тәңре кулы калдырган һәм хәзерге көндә, вакытлар узу белән берничек тә үзгәрмәгәнгә бернәрсәдән дә гыйбарәт булмаган үле матдә массасы кебек галәм һәм вакыт эчендә җәелеп яткан әзер продукт түгел».

Галәм үзе дә планеталарның һәм йолдызларның катып калган өере түгел, ул үсеп-үзгәреп тора — яңа планеталар һәм йолдызлар барлыкка килә, аларның кайберләре сүнә бара. Астрономнар Галәмнең киңәюен исбатладылар. Коръәндә дә шул турыда әйтелә: *«Ягъни китеп-килеп, күренеп һәм күренмичә йөрүче йолдызлар белән ант итәм»* [81:15—16]. Әгәр дә галактикалар, Җирдәге тормыш, кеше акылы һәм җәмгыять тә үзгәреш кичерәләр икән, ни өчен әлеге хәрәкәтне билгеләүче үзе дә үзгәрмәскә тиеш? Үсеш — абсолют, чөнки Алла үсеш кичерә, аның белән бергә яңа хакыйкатьләр барлыкка килә. Катып калган нәрсә үле дигән сүз.

Яшәү ни өчен һәм үлем ни өчен бирелә? Әйтелгән*: «Барча кеше үлем ачысын татучыдыр, Без сезне сырхау, ачлык кебек яманлык илә вә сәламәтлек, байлык кебек яхшылык белән сыныйбыз, яки савап белән гөнаһ арасында сезне сыныйбыз, боларны сезгә фетнә кылып сынау йөзеннән, соңра хөкем ителергә Безгә кайтырсыз»* [21:35]. Ни өчен яманлык һәм яхшылык белән сынарга кирәк соң?

Кешенең вазифасы үле материягә рух кертеп шул рәвешчә фани, матди дөньяны җиңүдән гыйбарәт. Аннан читләшү түгел, аңа рух өрү. Кеше таштан храмнар төзи, металл аппаратларны очарга мәҗбүр итә, планетаның тиз артучы халкын туендыру өчен яңа үсемлекләр китереп чыгара. Ул байлыкны кешеләргә хезмәт иттерә. Яхшылык һәм яманлык белән сынау киләчәк буыннарга кирәкле тәҗрибә туплар өчен кирәк. Кыямәт көнен — планетаның һәлакәтен нәкъ менә шулай гына кичектерергә мөмкин.

*«Кайчан күк ярылса. Вә йолдызлар чәчелсә. Вә дәрьялар агып бергә кушылсалар. Вә каберләр актарылып үлекләр терелеп чыксалар. Шул вакытта һәркем үзеннән элек ахирәткә җибәргән һәм үзеннән соң калдырган эшләрен белер»* [82:1—5].

Бүген сәнәгать эшчәнлеге нәтиҗәсендә климатның үзгәрүе, кешеләр барлыкка китергән корал, табигатьтән тиләләрчә файдалану планетаны һәлакәткә китереп, тирә-юньне җәһәннәмгә әйләндерергә сәләтле. Бу турыда Аллаһы Тәгалә дә кисәткән: *«Әгәр Җир каты тетрәү белән тетрәсә. Вә Раббыңның әмере килсә, вә фәрештәләр саф-саф булып килеп бассалар. Вә ул көндә җәһәннәм китерелсә, менә шул көндә адәм баласының исенә төшәр, алданганын белер, вәгазьләнергә бик теләр, ләкин эш узган булыр, кайда инде аңа хәзер искәрү, уяну файда бирсен? Эш узганнан соң адәм баласы әйтер: «Әйе, миңа үкенеч, кәшки дөньяда чагымда дини гыйлем өйрәнеп, ахирәтем өчен изге гамәлләр кылган булсамчы»,— дип»* [89:21—24]. Җәһәннәм — гөнаһ ияләрен яндыра торган физик ут түгел, җәһәннәм — рухи бушлыкны аңлау, кылынган яман эшләр өчен намус газабы — кеше фани дөньяда качарга тырышкан, ләкин киләчәктә кача алмаган нәрсә, байлыкның, артык муллыкның, ялганның һәм кеше үтерүләрнең, вакытны һәм көчне шәхси ихтыяҗларга сарыф итүнең мәгънәсезлегенә төшенү. Ә намус газабы физик уттан куркынычрак. Әйтелгән: *«Кыямәт көнендә залимнәрне эшләгән кабахәт эшләрнең газабыннан куркучы күрерсең, нәфескә, шайтанга ияреп Аллаһ динен бозучы залимнәргә бармыйча, кемгә булсын чәчләрен агартып, йөзләрен каралтып, өннәрен ала торган төрле куркынычлы газаплар? Вә ул куркынычлы газаплар аларны каршылап кочаклап алыр»* [42:22]. Теге дөньяда физик утлы җәһәннәмнең булуы мөмкин түгел.

Әгәр дә Җирдә экологик һәлакәт яки атом-төш сугышы килеп чыкса, моның нәтиҗәләре Коръән аятьләрендә сурәтләнгән җәһәннәм күренешләреннән бик күпкә куркынычрак булачак.

Кыямәт көне — тәкъдир дә, Хөкем көнен билгеләү дә түгел, бу — кисәтү. Әйтелгән: *«Кешеләрне Коръән белән вәгазь кыл, гафләттән уят, әлбәттә, син фәкать Аллаһ хөкемнәрен сөйләп ирештерүче генәсең. Син аларга ирекле түгелсең һәм аларның теләкләренә дә хуҗа түгелсең»* [88:21—22]. Бу — булуы ихтимал һәлакәт, «таулар тетелгән мамык кебек һавада очканда...», «күк ярылганда...». Әгәр кешеләр акылсыз булсалар, әгәр алар арасындагы каршылыклар өстенлек алса, һәлакәт котылгысыз булачак. Кеше табигать һәм башка кешеләр белән гармониядә яшәргә, шул рәвешчә Кыямәт көне килүне булдырмый калырга тиеш.

> *«Кяферләр синнән, Кыямәт кайчан була, дип сорыйлар. Кыямәтнең кайчан булачагын әйтүдә сиңа ни файда? Әйтсәң дә фәкать көферлекләрен арттырачаклар. Кыямәт вакытының ахыр чиге Аллаһка хастыр»* [79:42— 44].

Коръәндә күрсәтелүче җәннәт образы күбесенчә беркатлырак, ул, әлбәттә, салкынча күләгә һәм ясалма сугару турында хыялланган чүл кешеләренә исәпләнгән. Әйтелгән: *«Әмма иман китереп, Коръән тәгълиматы белән изге гамәлләр кылган кешеләрне тиздән асларыннан елгалар агучы җәннәтләргә кертербез, анда мәңге калганнары хәлдә аларга җәннәтләрдә пакь, гүзәл хатыннар булыр һәм аларны рәхәтлек күләгәсенә кертербез»* [4:57]. Тагын бер урында әйтелгән: *«Аллаһ, иман китереп, изге гамәлләр кылган мөэминнәрне асларыннан татлы елгалар агучы җәннәтләргә кертер, алар анда алтын беләзекләр вә энҗе ташлары белән бизәнерләр вә киемнәре яшел ефәктән булыр»* [22:23]. Төньякта исә сугаруның андый зур әһәмияте юк, чөнки анда болай да эзлекле төстә яңгыр явып тора, ә кеше анда, бәлки, салкынча күләгәдән бигрәк кояш турында хыялланадыр. Ачык ки, пәйгамбәр хакыйкатьне үз халкына аңлаешлы телдә җиткергән.

Гомумән әйткәндә, кайбер илләрдә комфорт җәннәттәге уңайлыкларга бик якын, хәтта алардан узып та киткән, шуңа күрә күпләрне Коръәндәге җәннәт рәхәтлекләре кайчандыр Гарәбстан чүлендә кәрваннар йөрткән гарәпне кызыктырган кадәр кызыктырмый да. Тәкъва кешене җәннәттә көтеп торучы келәмнәр һәм яшел мендәрләр белән бүген беркемне дә шаккаттыра алмыйсың. Җәннәт рәхәтлекләрендә хур кызлары белән әңгәмә корып яшәүне дә мәгънәле дип әйтеп булмый. Интеллектка ия замана кешесенә рухи сусауны басу физик ләззәтләр алуга караганда шактый әһәмиятлерәк. Цивилизацияле кеше өчен *«яхшы диваннарга таянганнары хәлдә, җимешләрнең һәм эчемлекләрнең төрлесеннән сорадылар»* [38:51] дип тасвирланган мәңгелек сурәте үз мәгънәсен югалта. Аллаһы Тәгаләнең кешелек өчен ахырда мондый язмыш ниятләве мөмкин түгел. Коръәндәге җәннәт күренеше исә мәҗүсилектән биздерү зарур булган урта гасыр кешеләре өчен язылган, ләкин ул үсешкә ирешкән, рухи бай кешеләргә яраклы түгел.

> *«Мәгәр Аллаһының ихлас колларына газап булмас, җәннәт нигъмәтләре булыр. Аларга җәннәттә теләгәннәре чаклы һәм алар теләгән вакытта төрле ризык булыр. Ул ризыклар төрле җимешләрдер һәм алар җәннәттә хөрмәтлеләрдер. Нигъмәтләр белән тулган җәннәтләрдә сыйланырлар. Яхшы диваннарга бер-берсенә каршы утырып рәхәтләнерләр. Хезмәтчеләр аларга савыт белән хәмер китерердер, ул хәмер җәннәттә елга булып агар. Ул хәмер сөттән ак булып, эчүчеләргә ләззәтледер. Ул җәннәт хәмерендә акылны җибәрмәк, вә башны авырттырмак юктыр, һәм аны эчеп дөньядагы кебек исер-*

*мәсләр дә. Вә яннарында хатыннары булыр, алар күзләрен үз ирләреннән алмаслар, башкага карамаслар, ул хатыннарның күзләре зур һәм матурдыр. Ул хатыннарның йөзләре аклыкта тәвә кошының йомыркасы кебек, анда аз гына сарылык булып иң матур төстер. Ул ләззәтле эчемлекләрне эчкәндә әйләнеп бер-берсеннән сорашырлар» [37:40—50].*

Җәһәннәмне һәм җәннәтне җирдәге куркынычлар һәм кеше сөенечләреннән торган матди картина итеп күзалларга кирәкми, асылы кешенең аң-белем чикләренә сыешмый торган символик билгеләр, образлар итеп аңларга кирәк.

Гомәр Хәйям язган:

Хөҗрәдә, синагогада, монастырьда
Кемдер курка җәһәннәмнән, кемдер җәннәт өмет итә.
Тик илаһи сергә төшенгәннәр йөрәгендә
Юктыр урын андый уйдырмага.

Эшлекле кеше буш әңгәмәләр корып вакыт үткәрә торган җәннәт турында хыяллана алмый. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә җәннәткә башка билгеләмә биргән: җаның ни тели, шуның булуы, «мәңгелек йорт»та хисапсыз бүләкләр. *«Коръән юлы илә изге гамәлләр кылучы хак мөэминнәр, җәннәт бакчаларында нигъмәтләр эчендә булачаклар, аларга Раббылары хозурында ни теләсәләр, шул булыр, бу нәрсәләр аларга Аллаһының олугъ юмартлыгыдыр»* [42:22]. Җәннәт ул — фани дөнья тәҗрибәсеннән торган рухи дөнья. Җәннәт — җирдә үткән юлыңның мәгънәле булуына ләззәтләнү.

*«Кыямәт көненә ышанып яхшылык эшләгән кешене Аллаһ бүләге көтә»* — Коръәндә шулай диелгән. Бу уңайдан сатулашып тору кирәк микән соң? Әгәр дә мин, инанып, кагыйдәләрне үз теләгем белән үтим икән, яхшылык өчен бүләкләү нигә кирәк? Игелек бу дөньяда да, теге дөньяда да бүләккә мохтаҗ түгел. Ул — үзе бүләк. Әйтелгән*: «Аллаһ үзе теләгән бәндәсен хисапсыз ризыкландырыр»* [2:212]. Өстәвенә һәркемгә үзе аңлаган һәм үзе көткән бүләкләр бирелә. Болай булгач, тәкъвалыкның мәгънәсе нидә? Җәннәттәге бүләкләргә омтылуның да, җәһәннәм утыннан куркуның да әһәмияте булмаса, тәкъва тормыш нигә кирәк? Мәгънә башкада. Әйтелгән: *«Алар җәннәттә буш сүзләрне вә гөнаһлы сүзләрне ишетмәсләр. Мәгәр сәлам бирешкән тавышны гына ишетерләр»* [56:25—26]. Шушы хакыйкатькә төшенү, рухият кертү һәм планетаны һәлакәттән коткару — тәкъвалыкның мәгънәсе нәкъ менә шушында инде.

*«Бер өммәткә дә әҗәле вакытыннан элек килмәс һәм вакытыннан кичекмәс»* [23:43].

Һәр илнең, һәр халыкның үз тарихы, үз вазифасы бар. Әйтелгән: *«Җирне халыклар өчен төзеп куйды»* [55:10]. Аллаһы Тәгалә халыкларны бер генә итә алмаганга түгел, яхшылык эшләүдә бер халыклар икенчеләрен узып китсеннәр өчен төрле итеп яраткан. Шәхсән минем үз халкымнан башка яшәвемнең мәгънәсе юк. Аллаһы Тәгалә теләсә, барлык кешене дә гарәп итәр иде һәм барысы да гарәпчә сөйләшер иде. Әмма ул телләрне күптөрле итеп яраткан. Галәм — төрле культуралы яңадан-яңа буыннарның тәҗрибәсен үзенә сеңдереп баручы илаһи гакылның һәм ихтыярның гәүдәләнеше ул.

Географик яктан гына түгел, культура ягыннан да Көнбатыш һәм Көнчыгыш чигендә торган татарлар үзләренең субцивилизациясен тудырганнар. Русиядә шәригать гамәлдә түгел, халыкның күпчелеге — православие вәкилләре. Мөселманнар тормышның шушы рәвешенә яраклашырга тиешләр. Мөселманнар өчен Русиядәге шартлар читтән дә кертелмәгән, көчләп тә тагылмаган — татарлар шушы илдә туган, алар аны чит түгел, үз иле дип саный. Бу ил мөселман дәүләтләреннән яхшырак та түгел, начаррак та түгел, ул — башка. Безнең язмышыбыз һәм безнең вазифабыз — шушы шартларда хак юлдан бару тәҗрибәсе туплау. Бездән Согуд Гарәбстаны ясап булмый һәм без, мөгаен, христиан Европасы да була алмабыз. Без ничек бар — шундыйлар. Русия җирендә хөрмә пальмасы үсми.

Русиядә миллионлаган мөселман үзләренең дөньяви илдә, аның гасырлардан килгән культурасы белән санлашып яшәргә тиешлегенә инанып үскән. Мөселман илләренең дин белгечләре безне яшәргә өйрәтә алмый, Согуд Гарәбстанында укып, андагы остазларына сукырларча ияреп баручы имамнар безнең тормышта каршылыклар һәм гауга гына китереп чыгарачак. Алар урта гасыр шәригатен катгый үтәргә өндәячәкләр, аның күпчелек нормалары һәм принциплары Русиядә үтәлә алмый.

Европа мөселманнары да шуңа охшаш шартларда яшиләр. Алар христиан дөньясындагы утраучыкларга тиң.

Дөнья катнаш була бара һәм Татарстанда «саф ислам»нан читкә тайпылу кебек кабул ителгән вазгыять киләчәктә күпчелек илләрдә норма булачак. Ислам хәлифәтләре чоры узды инде. Дөньяда бертөрлелек юк,

бар нәрсә бер-берсенә бәйле була бара. Беркем дә бер читтә аерым тора торган «саф ислам» тирәлеге булдыра алмый. Мондый «идеал»га омтылуның хаҗәте дә юк, чөнки ислам христианлыкны яки башка халыкларның тормыш рәвешен инкарь итми, ислам алар белән уртак тел табарга өйрәтә.

Татарстан югары технологияле продукция җитештерә, бу исә үз фәнни мәктәпләрен һәм югары белем системасын үстерүне таләп итә. Без ясаган вертолетлар, йөк машиналары, самолетлар көнбатыш фирмаларныкыннан начаррак булырга тиеш түгел, шуның өчен безгә Европаныкына якын стандартлар кертергә кирәк. Юкса без конкурентларыбызга оттырачакбыз. Бездә исламның европалашуы котылгысыз. Тормыш моңа мәҗбүр итәчәк.

Чынлап та, безгә кайсы якка юнәлеш алырга соң? Судангамы, Пакистангамы, Ирангамы, Согуд Гарәбстанынамы? Ил никадәр артта калган булса, тарихи шәригатьне шулкадәр күбрәк кертә. Алар үзләренә мондый экспериментлар рөхсәт итә алалар, ә татарлар өчен артта калу — үлеп бетү юлы. Хәзергә исә мөселман илләре вертолетларны һәм авыр йөк машиналарын Татарстаннан сатып алалар, һич тә киресенчә түгел. Шулай булгач, алар безне Көнбатышка конкурент булырга ничек өйрәтә алалар соң? Халык яшәешенең мәгънәсе — тәкъва мөселманнар булып үлеп бетүдә түгел, ислам тамырларын югалтмыйча, алдынгы халык булу ысулларын табуда.

Хәзерге заманның кайбер дин белгечләре прогрессның әһәмиятен аңлыйлар һәм Көнбатыш йогынтысыннан курыкмыйлар, шуңа күрә глобальләшү проблемасына шактый сабыр карыйлар. Мәсәлән, Фәрит Исак болай дип яза: «Берәүләр мөнбәргә күзәтчелек иткәндә, икенчеләр үз максатларында Интернеттан һәм телевидениедән файдалана алалар. Бүгенге көндә телевидениене кайвакыт барыбер хәрам (тыелган) дип белдерсәләр дә, без беләбез: әле кайчан гына, азан авазын көчәйтә торган репродукторларны да хәрам диләр иде. Димәк ки, тиздән «шайтан әрҗәсе» дә яхшы нәрсә дип белдереләчәк». Беренче карашка, бу бик алга киткән позиция булып күренә, чөнки ул традицион позициядән нык аерылып тора, ләкин, асылда, бу фикергә кимлек төсмере салынган инде — ислам прогрессның койрыгында. Әгәр дә без яңа техниканы һәм технологияне үзебез үк уйлап тапмыйбыз икән, бервакытта да мул тормышлы халык була алмыйбыз. Согуд Гарәбстаны нефть исәбенә көн күрә, ә без бары тик белем һәм яңа ачышлар исәбенә генә яши алабыз. Без үзебездә ваһһабичылыкка яки исламның башка төрле искереп беткән радикаль юнәлешләренә юл куя алмыйбыз.

Замана вазгыяте шундый: бик теләсәң дә, дөньядагы тенденцияләрдән читтә яши алмыйсың. Глобальләшү яңа технологияләр алып килә һәм тормыш рәвешен үзгәртә. Бүгенге көндә үз культураңны шушы процессларга яраклаштыру ысулын табу зарур.

Дөньяда шулай ук ислам глобальләшүе дә бара, ул Көнчыгышны гына түгел, Көнбатышны да колачлап килә. Европа үзәгендә мөселманнар халыкның шактый зур өлешен тәшкил итә. Франция, Германия, Бөекбритания, Голландия, Швейцария һәм Италия үсә баручы мөселманнар берлеге белән санлашырга мәҗбүрләр. Шул ук вакытта Европа берлегенә, андагы ислам элементын көчәйтеп, көньяктан Төркия омтыла. Көнбатыш глобальләшүе дөньяда каршылык тудыра, әмма ислам глобальләшүе дә күпләрне куркыта. Алар дөньяда гармония ясап бер-берсенә кушылырлармы яки бәрелешерләрме — барысы да безнең үзебездән тора. Гәрчә террорны ислам тудырмаса да, террорның гомумән дине булмаса да, 11 сентябрьдән соң дөньяда исламофобия арта.

Дөнья христианнарга, яһүдләргә һәм мөселманнарга бүленде, алар арасында упкынга әйләнүе ихтимал булган ярыклар хасил булды. Алар кешеләрнең җаннары аша узып, кешеләрне хәвефләндерәләр һәм куркыталар. Дөньяны яңа кыйммәтләр генә берләштерә ала. Алар чиста либераль дә була алмыйлар һәм традицион ислам кыйммәтләре дә түгелләр.

> *«Ий мөселманнар, ошбу ислам милләте бер шәригать булганы хәлдә сезнең динегездер, төрле юлга бүленмәгез, вә Мин сезнең Раббыгызмын, Миңа гына гыйбадәт кылыгыз!»* [21:92].

Коръән буенча, Ходай бер генә, әмма диннәр төрле. Коръән вәхиләренең Мәдинә чорын исәпкә алмасаң (ул чорның үзенчәлеге дошмани тирәлектә яшәүгә сәләтле ислам берлеге булдыру мохтаҗлыгыннан килеп чыга), калган урыннарында Коръән башка барлык диннәргә һәм яхшылык кылучы барлык кешеләргә карата түземле. Әйтелгән: *«Дөреслектә, гамәлсез коры ышанучылар һәм яһүдиләр, һәм насаралар, һәм ай, кояшка яки йолдызларга табынучылар — алардан Аллаһыга һәм ахирәт көненә ышанып, Коръән өйрәтүе буенча изге гамәлләр кылганнарына ахирәттә газап куркынычы булмас, һәм алар көенмәсләр»* [5:69]. Кайбер тәфсирләр бу аятьне, сүзгә-сүз, тексттан читкә тайпылып шәрехлиләр. Мәсәлән, Коръәнне «әл-Мөнтәхәб» (сайланма рәвештә) тәфсирләүдә ул мондый мәгънәгә ия булган: «Аллаһыга ышанучыларга, яһүдләрнең һәм төрле нәрсәләргә табынучыларның Мусага ияреп, насараларның Гайсәгә ияреп бер Ходайга, Яңадан

туу һәм әҗер алу көненә ихластан ышанганнарына һәм ислам шәригатьләрен үтәп яхшылык кылганнарына газап булмаячак, ә Яңадан туу көнендә хозурлык булачак». Чынлыкта исә Коръәндә сүз мөселман булмаганнарга шәригатьне үтәү таләбе турында бармый, анда аларга карата төп таләп — игелек кылу.

> *«Берәү явыз эш кылса, кылган явызлыгы хәтле генә җәза кылыныр, берәү мөэмин булганы хәлдә ирәк ир булсын, кирәк хатын булсын, гөнаһлардан сакланган хәлдә изге гамәлләр кылса, андый мөэминнәр җәннәткә керерләр, вә анда яхшы ризыклар илә хисапсыз ризыкланырлар»* [40:40].

Ходай өчен тәкъва булу өстенрәк, ләкин катгый таләп түгел. Кешеләргә игелек кылу — Аллаһы Тәгаләнең төгәл күрсәтмәсе, чөнки әйтелгән: *«Гамәлсез генә ышанучылардан, вә яһүдләрдән, вә насаралардан һәм төрле нәрсәләргә табынучылардан берәү Аллаһыга иман китереп Коръән, сөннәт дәлилләре белән изге гамәлләр кылса, андый мөэминнәрнең кылган әҗере Раббылары хозурында, аларга курку һәм кайгы булмас»* [2:62].

Барлык диннәр дә яхшылыкка өнди. Яһүд, буддачы, христиан яки башка берәү: «Улым, Ходай хакы өчен игелекле бул», — дип әйтә икән, димәк, аның йөрәгендә кешеләрне төрле юллар аша хакыйкатькә илтүче Аллаһы Тәгалә бар дигән сүз.

Ходай бер генә, әмма диннәр төрле һәм аерымлыклар күбрәк йолаларда, гореф-гадәтләрдә күренә. Әйтелгән*: «Дин тотучыларның һәр фиркасы өчен шәригать кылдык, һәрберсе үз динен тотар...»* [22:67].

Мөхәммәд пәйгамбәр яңа дин алып килдем дип расламаган. Ул монотеик (бер аллалы) традицияне дәвам иткән һәм башка дин вәкилләренә ихтирам уяткан. Ислам бер генә халыкны да кимсетми. Ислам динендә илаһи игелекләр бары тик аның дәвамчыларына гына булачак дигән дәгъва юк. Алар берninди искәрмәләрсез барлык халыкларга һәм барлык кешеләргә җибәрелгән, чөнки Аллаһы Тәгалә мәрхәмәтле һәм рәхимле. Шуңа күрә Муса Бигиев: «Бәхетсез адәмнәрнең берсе дә бу чиксез мәрхәмәттән мәхрүм булмасын өчен һәм кешеләр алдында Аның чиксез рәхимлегенең киң ачылган капкасы ябылмасын өчен, мин бөтен кешелек коткарылачак дип белдерәм. Әлеге мәсьәләдә минем иманым шул»,— дип раслаган. Ул «Ходай рәхмәтенең абсолютлыгы» дигән теорияне эшләгән, бу теория буенча Ходай рәхмәте тормышта нинди динне тотуларына карамастан, Ходай үзе бар иткән бар нәрсәгә кагыла. Әйтелгән: *«Һәм әйтерләр: «Ий Раббыбыз, Синең рәхмәтең, вә Синең белемең һәрнәрсәне сыйдырды...»* [40:7]. Әлеге аятьтән күренә ки: Ходай мәрхәмәте мөселманнарга гына түгел, һәрбер кешегә насыйп нәрсә. Мәңгелек белән чагыштырганда, безнең гомер бары тик бер генә мизгел. Әгәр дә Аллаһы Тәгалә мөселман булмаганнарның барысын да, ягъни кешелекнең күпчелек өлешен мәңгелек газапка дучар итсә, илаһи ачу илаһи мәрхәмәттән күпкә өстен булып чыгачак.

> *«Минем мөэмин бәндәләремә әйт: «Ий бәндәләрем, гөнаһ кылып үзегезгә зарар иткән булсагыз, Аллаһының рәхмәтеннән өмет өзмәгез, чөнки тәүбә итеп төзәлгәндә, Аллаһ гөнаһларны ярлыкаучыдыр, Ул — Аллаһ ярлыкаучы, вә рәхимледер»* [39:53].

Җәза котылгысыз, ләкин ул мәңгелек түгел. Муса Бигиев раславынча, «җәһәннәм юкка чыгачак», чөнки Ходайның рәхмәте чиксез. Ходай Тәгалә кыска гына фани тормыштагы гөнаһлар өчен кешенең җанын мәңгелек җәзага дучар итә алмый. Муса Бигиев болай дип язган: «Үз рәхмәтенең чиксез дәрьясын күрсәтер өчен һәм аны мәңгеләштерер өчен Аллаһы Тәгалә бар кешеләргә дә уртак рәхмәтен биргән. Аның чикләре юк һәм ул мәңгелеккә калачак. Кешеләрне фани дөньяда ялкаулыктан һәм вакытны бушка сарыф итүдән коткару һәм яман гамәлләрдән тыю өчен белдерелгән аерым рәхмәтне Ул игелек кылган, тәкъва һәм игелекле яшәгән, тирә-юньдәге кешеләргә зыян салудан тыелган һәм камилләшү юлыннан барган кешеләргә бирә».

Кешелек, барлык эчке каршылыкларга карамастан, уртак бергәлек — өммәт тәшкил итә, анда мөселман һәм башка төрле берлекләр дә, дингә ышанмаучылар да бар. Әгәр алар игелек кылалар икән, Ходайга шулай кирәк дип санап, аларны дошман дип атарга ярамый. Чынлыкта исә бу Коръән аятьләренең тирән мәгънәсенә төшенмәгән экстремистларга кирәк. Ходай Тәгалә игелек эшләгән кешене кабул итә. Әгәр дә инде ул шул ук вакытта дин дә тота икән, ул Ходайга тагын да яраклырак.

> *«Аллаһ — безнең Раббыбыз, һәм сезнең Раббыгыздыр. Безгә — безнең гамәлләребез, сезгә — сезнең гамәлләрегез. Безнең илә сезнең арада хосумәт вә низаг юктыр. Аллаһ Кыямәт көнне барчагызны да бер урынга җыяр, вә ахырда кайтмак Аллаһыгадыр, дип»* [42:15].

Ислам Җиргә кешене коллыктан һәм бәйлелектән коткаручы погресс сыйфатында җибәрелгән, ул — гаделлекнең, рух хөрлегенең, белемгә омтылышның үзе. Ислам сабырлыкка өнди һәм көчләүгә каршы чыга.

Кайчандыр сугышчанлык барлык диннәргә дә хас сыйфат булган. Мөселманнар хәлифәтләрне кылыч тотып төзегәннәр. Европа христианнары тәре походлары оештырганнар. Католиклар һәм протестантлар бер-берсе белән рәхимсез сугышканнар. Ләкин кылыч кынасына салып куелган инде. Безнең дәвердә аны кире чыгаруның кирәге юк, чөнки ул кылыч иясенең үзенә каршы юнәлергә мөмкин. Һәрбер дин яхшылыкка һәм шәфкатькә өнди, кешелекне нәкъ менә шушы хәл бер өммәт итә дә инде.

> *«Китап әһелләре белән низаглашмагыз, мәгәр күркәм юл белән сөйләшегез, әгәр алар нинди юл белән булса да золым итсәләр, ул вакытта аларга катылык кылыгыз, әгәр алар сезнең белән әрепләшсәләр, әйтегез: «Аллаһыдан сезгә һәм безгә иңгән китапларның һәммәсенә иман китерегез, сезнең һәм безнең Илаһыбыз бер генә Аллаһтыр, без Ул — Аллаһыга итагать итәбез»* [29:46].

Эзләнүчән һәрбер кешенең хакыйкатькә үз юлы бар. Һәрбер халыкның үз вазифасы бар. Татарлар өчен котылу үткәндә түгел, киләчәктә, безнең прогресска юлны җәдидчеләр салган, алар пәйгамбәрнең васыятьләрен үтәп, ислам реформасын башлаганнар. Без аны кешелек тудырган хәзинәләргә юнәлеш тотып дәвам итәргә тиеш.

Европа безнең өчен һәрвакыт зирәклек һәм белем чыганагы булды. Ул хәзер дә шулай булып кала. Безнең бурыч — татарларны башка халыклардан аерып торучы киртә төзү дә, ясалма этноконфессиональ резервациягә йомылу да түгел, ә төрле диннәр арасында, исламны төрлечә шәрехләүләр арасында, ислам һәм христианлык арасында күперләр салу. Безнең миссия бар кешелекне уртак төеннәр белән бергә бәйләргә ярдәм итүче үзара аңлашуны җәелдерүдән гыйбарәт.

> *«Тәхкыйк Аллаһ бер каумгә биргән нигъмәтен үзгәртмәс, хәтта ул каум үз хәлен үзгәрткәнгә чаклы...»* [13:11].

Кешеләр үз тормышларын үзләре үзгәртмәсә, Аллаһы Тәгалә бу тормышта бернәрсәне дә үзгәртми. Пәйгамбәр әйткән: «Үз өстегезгә кулыгыздан килерлек эшләрне генә алыгыз, чөнки сез үзегез алардан туймас борын Аллаһы Тәгалә туймас...» Миннән мөселман йолаларының барысын да үтәүне таләп итәргә кирәкми, мин үз өстемә үземнең көчем җитәрлек нәрсәләрне генә — фәннәрне өйрәнүне һәм кешеләргә хакыйкатькә якынаерга булышуны гына алам, ә пәйгамбәр: «Кем башкаларны өйрәтү максатында күпме булса да фән өйрәнә — шуңа Аллаһы Тәгалә җитмеш изгенең котылу чарасын бирер»,— дигән. Минем котылу чарам төрле конфессия һәм төрле культура вәкилләренең үзара аңлашуына ярдәм итүдән гыйбарәт. Мин беләм, бу фикер дин әһелләренең күбесенә ошамаячак. Мәгълүм ки, хурлаганда түгел, мактаганда яшәү җиңелрәк. Ләкин әйтелгән: *«Эшләрегездә Аллаһ боерганча туры булыгыз!»* [11:112].

Шушы фикерләремне язып, мин кемнедер гаепләргә, нәрсәнедер инкарь итәргә теләмәдем. Мин бары тик хакыйкатькә юл эзлим. Пәйгамбәребезнең исламны яңарту турындагы сүзләрен тотарга кирәклегендә шигем юк. Бу бүгенге көндә иң мөһиме, чөнки без яңа гасырга аяк бастык.

Мин язганнарны бидгать дип атау — иң җиңел эш. Ләкин пәйгамбәр сүзләрен истә тотарга кирәк: «Үз хаталарыгызны карагыз. Бу сезне башкаларның хаталарын эзләүдән тыяр. Бервакытта да башка кешеләр эшеннән хата эзләмәгез, чөнки үз хаталарыгыздан арынмас борын башкаларның хатасын күрсәтү — гөнаһ».

> *«Гыйбадәт кылырга яраклы һичбер зат юк, мәгәр Аллаһ үзе генә, Ул һәрвакыт тере, бөтен нәрсәгә хуҗа булганы хәлдә һәрвакыт бар. Аны ару, талу һәм йокы тотмас, җирдә һәм күкләрдә булган нәрсәләр аныкыдыр. Ахирәттә Аллаһ хозурында кем кемгә шәфәгать кылыр? Юк, шәфәгать кылучы булмас, һичкем үз теләге белән һичкемгә шәфәгать кыла алмас, мәгәр Аллаһ рөхсәте белән генә шәфәгать кылучы булыр. Аллаһ кешеләрнең үткәндәге барча эшләрен һәм алдагы барча эшләрен белер, кешеләр Аллаһ белеменнән һичнәрсәне чолгап ала алмаслар, мәгәр Аллаһ белдергәнне генә белерләр. Аллаһының бушлык урыны җирне һәм күкләрне сыйдырды, Аллаһыга җирне һәм күкләрне саклау авыр түгел, ул Аллаһ дәрәҗәдә бик бөек һәм бик олуг. Дингә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар. Ясалма, ялган, батыйль диннән Аллаһ төзегән хак дин ачык аерылды»* [2:255—256].

Борынгы заманнарда да, хәзерге тормышта да Аллаһы Тәгалә кешене рухи һәм югары кыйммәтләрне, мәңгелекне һәм игелекне эзләүдә, Галәм һәм вакытның чиксезлеген, материя һәм рух катлаулыгын аңларга омтылышында үз ярдәменнән ташламаган. Әгәр дә котылырга телисең икән, яшәүнең мәңгелегенә ышаначаксың. *«Ий каумем, бу дөнья тереклеге тиз бетәчәк, бик аз нәрсәдер, әмма ахирәт исә мәңгегә бетми торган карарланачак яхшы урындыр»* [40:39]. Дин кеше җанын югары идеал белән рәттән куя, гадәти игелекләрдән югарырак күтәрә, яхшырак тормышка омтылыш тудыра.

Дингә ышану символы гади сүзләрдән гыйбарәт: «Аллаһтан башка Тәңре юк һәм Мөхәммәд — Аның пәйгамбәре». Шушыны әйткән кеше — мөселман. Моны инкарь итүче — динсез, ә кешенең җанын бары тик Аллаһы Тәгалә генә күрә ала һәм кешеләрнең тәкъвалыгына бәя бирергә бары тик аның гына хакы бар.

Үзенә 950 яшь тулгач, Нух, көрсенеп, болай дигән:

— Йа Ходам, гомер шундый кыска! Адәм баласы туарга да өлгерми, инде үләр вакыты җитә!

Без барыбыз да Юлда һәм калган гомеребездә күп яхшылыклар эшләп калырга кирәк.

## ТАТАР РУХЫ

*(Төрки-татар цивилизациясе мәсьәләсенә карата)*

*«Төрки бәкләр халкы, моны ишетегез! Төрки халкының берләшеп, ил тотачагын биредә чокып яздым, ялгышлар аркасында бүлгәләнеп үләчәгегезне тагын монда чокып яздым, әйтергә теләгән сүзләремне мәңгелек ташка чокып яздым. Аны күреп белегез, төрки — хәзер бәк халык!»*

Йолыгтәгин. Күлтәгин истәлеге
Кече язма. 732

### «Каһәрләнгән» сораулар

*(Кереш сүз урынына)*

арих — кеше рухының әверелешләре, вакыйгалар барышын билгеләүче бөек идеяләрнең үсеше ул. Рух юкка чыга икән, тормыш та әкренләп туктала, дәүләтләр җимерелә, халыклар юкка чыга, алар турында бары тик хатирәләр генә кала. Материя — аның тересе дә, үлесе дә — идея аркасында гына мәгънәгә ия.

Бөтен сугышларның, сәүдәнең, шәһәрләр салынуның, дәүләтләр төзелүнең һәм аларның таркалуының, матди һәм матди булмаган һәйкәлләрнең артында тарихны хәрәкәткә китерүче нәрсә — халык рухы тора. Бөек шәхесләр, җиңүләр һәм җиңелүләр, бөек һәйкәлләр турында сөйләгәндә, чынлыкта без рух әверелешләрен — ягъни вакыйгалар барышына мәгънә бирүче бердәнбер нәрсәне тасвирлыйбыз. Кеше фикеренең үзгәрешләре чылбыры күрсәтелмәгән булса, дөнья картинасы юкка чыга, ул инде бары археология табылдыклары җыелмасы, өзек-төтек хатирәләр һәм әдәби истәлекләр генә булып кала.

Рух сүнү — халыкның дөнья аренасыннан юкка чыгуына бәрабәр. Аның исеме елъязмада һәм топонимикада кала, ә рухы үзгәрешкә дучар булган халык, бүтән культура эчендә эреп, бүтән рәвешкә керә, ихтыяры көчлерәкләр тарафыннан йотыла.

Идеянең иясе гаять зур тарихи вакыйгаларны хәрәкәткә китерүче була ала. Атасының казанышларын дәвам итеп гаять зур империя төзегән Александр Македонский әнә шундый булган. Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган нәселе — корәйшитләр дә башта яңа динне кабул итмәгәннәр. Чыңгыз ханның дөньяны яулап алуының бернинди дә икътисади яки хәрби алшартлары булмаган, бары тик рух көче, үз максатына ирешү теләге булган. 1916 елга кадәр большевиклар — беркемгә дә мәгълүм булмаган фикердәшләр түгәрәге генә. Хакимияткә көчле омтылыш нәтиҗәсендә коммунистик Интернационал оештыра алганнар. Дөнья бу кешеләрне көткән, һәм алар зур-зур массаларны хәрәкәткә китергәннәр.

Без барыбыз да — объектив законнар буенча хәрәкәтләнгән сыман тоелган гомумтарих агымының бер өлеше. Әмма көчле ихтыяр агымның юнәлешен үзгәртә дә ала. Көтү үзенең башлыгы артыннан чапканда, якыннан карасак, без аерым атларның тояклары уйнаклавын, мускуллары киерелүен, аларның көтүдән калышмаска теләп алга ыргылганын күрәбез. Кош очышы биеклегеннән карасаң исә, күз алдында, алдан башлыгы чаба торган тоташ бер ташкын ачыла, көтү башлыгы бу ташкынны уңга да, сулга да бора ала яки барысын да упкынга юнәлтә ала. Безгә бөтен нәрсәне дә бу дөньяның көчле яки бай кешеләре хәл итә кебек тоела, ә чынлыкта исә бар хәрәкәт актив кешеләргә бәйле, вакыйгалар барышын шулар билгели, чөнки алар күңелендә үзгәрешләргә ашкыну яши, нәкъ менә шундый кешеләргә язмыш үз тамгасын сала да. Эн-

тузиастлар тырышлыгына башкалар ярдәме дә кушылса, күмәк үзаң революция кичерә. XX гасыр Ленины кебек, Чыңгыз хан да урта гасырларда дөнья картинасын үзгәрткән.

Кеше өч үлчәм кысаларында фикер йөртә: пространство, вакыт, материя. Хәрәкәт материянең эчке табигатенә хас үзенчәлек итеп фикерләнә. Әмма тормыш материя түгел, материя тышчасына төрелгән рух ул. Кешелекнең яшәеш мәгънәсе рух үсешеннән гыйбарәт. Икътисад, техника, технология, машиналар һәм кораллар — рух торышын күрсәтүче тышкы билгеләр генә ул. Рух хәрәкәтен бернинди акчалар да алдан билгели алмый — бу дөньяда бөтен нәрсәне дә сатып яки сатып алып булмый. Әмма рух әверелешләре материянең Галәмдә һәм вакытта үсешен билгели.

Рух әверелешләре шаккаттыргыч. Алар табигать үзгәрешләре кебек үк серле. Мәсәлән, ваемсыз күбәләк бирән кортны тудыра, корт исә, тут агачы кимереп, ефәк җепле кузы ясый. Бу әверелеш бигрәк тә шунысы белән гаҗәп: меңнәрчә еллар буена ымсындыргыч байлык символына әйләнеп, ефәк Европа һәм Азия тарихының үзәгендә булып чыккан. Ефәк күп халыкларның язмышын кискен үзгәрткән. «Бөек ефәк юлын» кулга төшерү өчен сугыш арты сугышлар кабынган, күпме дәрт-дәрман, көч сарыф ителгән, ефәк сәүдәсенә ия булырга омтылып күпме дәүләтләр баеган һәм юкка чыккан.

*«Гамәлләрне күзәт һәм уңайлы форсат көт, тиешле вакыт җиткәч, аннан файдалана бел, сабырлыкны акыл белән куш, тут агачының яфрагы шул рәвешчә ефәккә әйләнә».*

*Ибне Гарәбшаһ. XV гасыр*

Тарих — әверелешләр чылбыры ул.

Халыклар үз йөзләрен һәм исемнәрен үзгәртәләр, тулы бер мәмләкәтләр юкка чыга, алар урынында яңалары барлыкка килә. Күчмә халык шәһәрләр сала башлый, ә шәһәр кешеләре «казак»лар булып китеп яшәү рәвешләрен үзгәртәләр. Кайчандыр коточкыч юлбасарлар булган викинглар белемле һәм тыныч скандинавия кешеләренә әвереләләр. Таркалып баручы Руська исә Чыңгыз хан рухы кереп оялый һәм Мәскәүдән, орлыктан шытып чыккан сыман, олы ил үсеп чыга.

Заманча үзаң — территориаль, утрак фикер йөртү ул. Татар тарихын без Татарстанда эзлибез һәм Киев Русенда — нәкъ менә урыслар, ә Борынгы Римда — латинлылар яшәгәнлегендә шигебез юк. Чынлыкта исә күпчелек халыклар һәрвакыт күченеп, бер-берсе белән аралашып яшәгәннәр. Бер генә халыкның да мәңгегә үзенә беркетелгән биләмәсе булмаган.

Киев башта Куяба исемле хәзәр шәһәре булган, анда славяннар гына түгел, төркиләр дә: хәзәрләр, торкилар, каракалпаклар да, берендейлар да яшәгән. Соңрак викинглар килеп кенәзлек иткәннәр. Аннан соң башка төрки кабиләләр — печенеглар, кыпчаклар, татар-монголлар, шулай ук литвалар һәм поляклар пәйда булган. Культура катламнарының шушы катнашмасыннан урыс рухы ясалган. Анда славян һәм төрки кушылып болгатылган.

Татарларның борынгы бабалары (төрки телле һуннар) Азия төпкелләреннән Көнбатышка таба хәрәкәт иткәннәр һәм безнең эрага кадәр 155 —158 еллар да Идел-Урал төбәгенә килеп утырганнар. Урыслар Идел елгасы буена күпкә соңрак — мең елдан соң гына барып чыкканнар. Болар бар да күченеп йөргән һәм берберсе белән аралашкан: йә нindидер симбиозга берләшкәннәр, йә параллель культуралар тудырганнар, йә бер-берсенә каршы сугышканнар.

X гасырда һуннарның көнчыгыш тармакларының берсе — болгарлар, Көнбатыш Төрки каганлыгы таркалганнан соң, бер үк вакытта Дунайда һәм Иделдә мөстәкыйль дәүләтләр төзегәннәр. Кубрат ханның бер улы — Аспарух — славяннарны, икенче улы Идел буенда төркиләрне һәм фин-угырларны берләштергән. Дунайда христиан Болгарстаны һәм Урта Иделдә мөселман Болгарстаны барлыкка килгән. С.М.Соловьев болай дип язган: «Борынгы заманнарда, урыс славян кешесе Ока елгасы буенда христиан чиркәүләре төзи башлаганчы, бу җирләрдә Европа мәдәнияте (гражданственность) урнашканчы ук, болгар кешесе Идел һәм Чулман буйларында Коръән тыңлаган. Биредә Төньяк-Көнчыгыш Европада беренче мәртәбә христианлык басурманлык белән бәрелешкән. Бу бәрелеш зарури булган, чөнки тиздән яңа Русь Югары Идел өлкәсендә төпләнгән һәм славян колониясе бу елганың түбәнге агымына үткән, Төньяк-Көнчыгыш Русьның беренче кенәзләре — Юрий Долгорукий, Андрей Боголюбский, Всеволод III, Юрий II болгарларга каршы сугыш алып барганнар һәм, үз биләмәләренең чикләрен Идел буенда Ока тамагына кадәр җиткереп, аларны Түбән Новгород белән беркетеп куйганнар». «Бөек урыс елгасы» Волгадан алдарак бөек татар Иделе аккан. Төрки-татарлардан аермалы буларак, урыслар Көнбатыштан Көнчыгышка таба Татар бугазынача барганнар, аннары хәтта Аляскага да җиткәннәр.

Төрки-татарлар элек-электән үк бик зур территория биләгәннәр, шуңа күрә этник тамырларыбызны бер үк вакытта Кытайның төньягыннан да һәм Дунай буйларыннан да эзләвебез табигый. Территориаль фикер

йөртү культура әверелешләренең бөтен колачын һәм тирәнлеген күзалларга комачаулый. Тарихны аңлар өчен күчмә халыкныкы кебек экстерриториаль карашлы булу кирәк.

Без тарихны гади итеп аңлатып бирүләрен телибез. Еш кына мондый сорау ишетәсең: «Татарлар болгарлармы, әллә монголлармы?» Юк, алар — татарлар. Һәм мондый җавап әлеге сорауга бернинди дә ачыклык кертми кебек. Әмма башкача җавап бирсәң дә, берни аныкланмый. «Татарлар» этнонимы үз тормышы белән яшәгән, ә халык төрки һәм төрки булмаган культуралардан үзенә күп нәрсә сеңдергән. Һуннар — төркиләр — болгарлар — татар-монголлар — хәзерге заман татарлары. Этногенез формуласы менә шундый. Татар этногенезында ике куәтле агым — һун-төрки һәм төрки-татар бергә кушылган. II гасырда Европага ыргылып кергән һун-төрки дулкыны үзеннән соң Идел һәм Дунай буйларында болгар дәүләтчелеге калдырган, ә төрки-татар агымы күпсанлы төрки кабиләләрне төрки-татар халкына әверелдереп, болгар һәм кыпчак тирәлегендә тамыр җәйгән. Халыкның физик яшәешенә яки этноним язмышындагы үзгәрешләргә һәрвакытта да туры килми торган рух үсешеннән мөһимрәк нәрсә булырга мөмкин соң? Татар рухының сүрелү сәбәбен аңлау мөһим. Ни өчен Казанны алырга Явыз Иван белән бергәләп Шаһгали җитәкчелегендәге татарлар да барган? Шуннан соң татарлар Русия эчендә югалып калганнар. Татар рухын кабат тергезү мөмкинме? Үз заманында һуннар Алтай таулары аша, сугыша-сугыша Идел буена бәреп кергән һуннар әнә зәгыйфь кабилә булганнар һәм тарихтан 200 елга юкка чыкканнар, әмма соңрак, угырлар белән кушылып, бөтен Европаны дер селкеткән дәһшәтле һуннарга әверелгәннәр. Аларның рухы яңарган. Бәлки, татар рухы тулысы белән урысларга күчкәндер? Русиянең дәүләтчелеге генә түгел, урысларның культурасы да башлыча Мәскәүгә хезмәт итәргә киткән татарлар энергиясе ярдәмендә формалашкан бит.

Татарлар бөтен дөньяны буйсындырырга тырышканнар һәм үзләре буйсындырылганнар. Алар Чыңгыз хан идеяләрен Мәскәүгә мирас итеп тапшырганнар, ә Мәскәү исә дәүләт экспансиясен православие-Византия мессиячелеге белән бәйләгән һәм шушы җирлектә урыс идеясе барлыкка килгән. Баштарак бу идея «Мәскәү — өченче Рим» дип тәгъбир ителсә, соңрак «Мәскәү — Коммунистик Интернационал башкаласы» рәвешенә керде. Алда тагын ниләр көтә микән?

Русия тарихында XIX гасыр — дөнья проблемаларына киеренке рәвештә җаваплар эзләү вакыты иде. Алманнар һәм французлар дәрәҗәсе белән чагыштырырлык фикер югарылыгы, атаклы исемнәр, әдәбиятта, шигъриятtә, музыкада һәм сәнгатьтә күренекле әсәрләр... XIX — XX гасырда дөнья культурасы урыс культурасы йогынтысын тоеп үсә.

Славянофиллар һәм көнбатышчылар арасындагы идея бәхәсе Пушкинны, Аксаковны, Чаадаевны, Достоевскийны, Толстойны биргән. Бүген исә көнбатышчылар һәм көнбатышка каршылар мәйдан тота. Юрий Афанасьев, Геннадий Бурбулис, Гавриил Попов, Анатолий Собчак, Егор Гайдар — әлеге лидерлар Мәскәүдәге күпсанлы митинглар, гыйльми җыелышлар аркасында үсеп чыктылар һәм сәясәт күгендә кометалар көтүе сыман ялтырап алдылар, алар артыннан якты, ләкин кыска вакытлы эз калды. Кемнәрдер теләк теләргә өлгерде, ә кемнәрдер — юк. Бу төркем әле исән, аларның чырайлары телеэкраннарда күренгәләп ала. Әмма алар үзләре инде тарихка күчтеләр. Алар яклаган карашларны искә төшерү дә кыен хәзер. Алар оныттылды. Алар демократиянең Русиягә яраклы һәм аңлаешлы кыйммәтләрен үстерә алмадылар. Лев Аннинский билгеләп үткәнчә, «ул либералларга Русия кызык түгел!». Көнбатыштагыны күчер дә утырт — алардан соң бары шундый тойгы гына калды.

1988 елда «Иного не дано» дигән атаклы мәкаләләр җыентыгы нәшер ителде. Бу китапны бөтен кеше кырылып укыды, ул «Үзгәртеп кору» дәверенең идея байрагы булды. Ун елдан соң әлеге җыентык авторлары тәэсир уртаклаштылар. «Җыентык чыккан елны бу авторлар чын-чынлап фикер хакимнәре иде,— дип искә төшерә Юрий Афанасьев.— Шуңа күрә бу китапның иҗтимагый фикергә йогынтысы үтә көчле булды. Хәзерге вакытта андый фикер хакимнәре юк. Бу нормаль хәл дип уйлыйм. Зыялылар арасындагы таркаулык, фикер үсешендә якты маяклар булмау — нормаль күренеш. Димәк, тормыш җайлана, димәк, кеше үз язмышын үзе хәл итәргә сәләтле, ул үзенә нәрсә бирелгәнен һәм бирелмәгәнен үзе аңлый». Моның белән килешү авыр. Җәмгыятьтә «фикер хакимнәре» булмау нормаль хәл түгел. Лев Толстой яки Федор Достоевский булу начармыни? Григорий Водолазов сүзләрендә дөреслек күбрәк: «Без, гадәттәгечә, кабат уңышсызлыкка дучар булдык. Иҗтимагый һәм демократик энтузиазмны җилгә очырдык». Үзгәртеп кору идеологлары совет җәмгыятен бары тик тәнкыйть кенә иттеләр, үзләре үзенчәлекле юллар тәкъдим итә алмадылар. «Демократияне, көнбатыш модельләренә нигезләнеп, гомумтигезлек һәм чәчәк ату дип тонык күзаллаулар бар иде, әлбәттә,— дип раслый Андрей Нуйкин,— ләкин көрәшче-реформаторларның күпчелеге безнең уникаль вазгыятьтә бу модельләргә ничек якынаерга икәнлеге турында уйларга да теләмәде». Һәм, өметсезләнеп, өстәп куя: «Шушы еллар буена безнең профессиональ икътисадчылар, идеологлар, политологлар, психологлар, культурологлар өере кайда булган соң?» Әйе, «үзгәртеп кору» бик күп тәнкыйтьчеләр тудырды.

Тормыш «иное», ягъни башка юллар да барлыгын раслады. Рухи остазлар «каһәр суккан» сорауларга җавап бирмәсә, «фикер хакимнәре» булмаса, башка көчләр барлыкка килә: милләтчеләр, сепаратистлар, шовинистлар, экстремистлар, фашистлар.

«Русия фашист дәүләте булачакмы?» дигән сорауга Александр Севастьянов болай дип кырт кисә: «Әйе, булачак. Һичшиксез. Котылгысыз рәвештә. Мәҗбүри». «Фашизм — милли капитал диктатурасы,— дип дәвам итә ул.— Ким дә түгел, артык та түгел, нәкъ шулай. Менә нәрсә турында уйларга кирәк. Милли капитал диктатурасы... Нәкъ менә шушы нәрсә Русиягә ашарга ипи, суларга һава кебек зарур. Бүгенге кебек интернациональ түгел, ә нәкъ менә милли! Милли капитал ныгып бергә туплангач, безнең сәнәгатьчеләр, сәүдәгәрләр һәм финансчылар үз илендә ялчы түгел, хуҗа булырга кирәклеген һәм мөмкинлеген ахырынача аңлап алгач, мондый диктатура хәзерге вазгыятькә җавап рәвешендә һичшиксез барлыкка киләчәк». Ул моны 1995 елда язган. Бүген скинхедлар инде бөтен ил буйлап атлый. Русиядә фашизм тәгълиматтан чынбарлыкка күчте.

Русия тарих чатында тоткарланып калды. Ул империя традицияләреннән дә китеп бетә алмый, шул ук вакытта демократик дәүләт тә була алмый. Күпләргә азрак кына артка чигенеп куярга, нәрсәләрнедер азмаз Көнбатыштан, аз-маз Көнчыгыштан алырга һәм ниндидер идеаль империя төзергә мөмкин сыман тоела. «Яңа империя, ягъни көчле милли идеяле яңа үтә милли дәүләт фашистик яки коммунистик мутациягә һәм либераль «таркау склероз»га альтернатива булырга мөмкин һәм тиеш тә,— дип яза «Милли манифест» авторлары.— Аның үзәгенә совет заманының уңай традицияләрен дә үз эченә алган Русия үсеше традицияләре һәм урыс фәлсәфи фикере казанышлары, аерым алганда, Вернадский эшләгән, кешелекнең ноосфера аша үзара тәэсире концепциясе белән берләштерелгән иң яңа, хәтта үтә яңа көнбатыш идеяләре салынырга тиеш. Ул дәүләттә XXI гасырның киләчәк динамизмы һәм безнең илнең бөек рухияте, демократия кыйммәтләре һәм милли мәнфәгатьләр, базар икътисады механизмнары һәм милли идея үзара ярашырга тиеш. Болар барысы да ни Көнбатышта, ни Көнчыгышта эзләп-эзләп тә табылмый торган ниндидер абсолют яңа бер нәрсәгә әверелер». Төгәл анализны изге ниятләр белән алмаштыру — фикер йөртүнең инде таныш стиле бу. Проблема исә нинди «үтә яңа идеяләр» алырга кирәклеген төгәл әйтүдән гыйбарәт. Демократик кыйммәтләрне һәм базар икътисады механизмнарын алырга өндәү кирәкми. Алар безнең тормышта бар инде, әмма алар начар. Хикмәт империяне яхшыртуда түгел, ә бәлки аны бөтенләйгә җирләп куюда. Русия — үзенчәлекле ил. Ләкин дөнья тенденцияләренә каршы барырлык дәрәҗәдә үк түгел. Русияне акыл белән аңлар, аршын белән үлчәр һәм исәп-хисап нигезендә идарә итәр вакыты җитте.

Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында яки алар өстендә тору түгел, икесенең берсен сайлап алыр чак җитте. Киев Русе Көнбатыш түгел, ул чорда көнбатыш төшенчәсе әле булмаган, ә көнчыгыш инде булган. Николай Бердяев: «Барлык бөек диннәр һәм культуралар бишеге — Көнчыгыш»,— дип язган. Соңыннан Көнбатыш формалашты, ә Көнчыгыш күптөрлегә әйләнде, көнчыгышлар күбәйде: Көньяк-Көнчыгыш Азия, Урта Азия, Гарәп дөньясы, Якын Көнчыгыш — һәм алар барысы да төрле-төрле. Русияне Көнчыгыш-Көнбатыш кебек урталык патшалыгы итеп шәрехләргә ярамый. Андый цивилизация юк. Чаадаев сүзләрендә хаклык күбрәк, мөгаен; ул бервакыт болай дип әйткән: «Без Көнбатышныкы да, Көнчыгышныкы да түгел, бездә ни тегесенең, ни монысының традицияләре юк. Без вакыттан читтә торган шикелле, безгә кешелекнең бөтендөнья тәрбиясе кагылмаган». Ул Русиянең дөнья культурасына керткән өлешен бик кырыс бәяләгән: «Без дөньяда ялгыз, без дөньяга бернәрсә дә бирмәдек, аны бернигә дә өйрәтмәдек, кешелек идеяләре массасына без бер генә идея дә кертмәдек, кеше акылы прогрессына берни белән дә ярдәм итмәдек, ул прогресстан безгә кергән нәрсәләрне исә бозып бетердек». Чаадаев әлеге юлларны язганда, әле Толстой да, Достоевский да, Чехов та, Бердяев та булмаган. Әмма бүгенге тормышны текәлебрәк күзәтсәң, аның сүзләре искә төшә. Көнбатышның барлык алдынгы идеяләре Русия җирлегендә үзенең капма-каршысына әйләнә дә куя. Демократия монда күбрәк анархиягә охшый, хокукый тәртип исә авторитаризмны хәтерләтә. Хосусыйлаштыру дигәннәре халыкны талау булып чыкты, фермерчылык авыл хуҗалыгын һәлакәткә китерде, җирле үзидарә гомумән берни дә түгел. Теләсә кайсы яхшы идея Русия шартларында бозыла-пычратыла. Ни өчен шулай соң бу? Ихтимал, әлеге сорауга җавап шул ук Чаадаев сүзләрендәдер: «Русия турында сөйләгәндә, аны башка дәүләтләр кебек үк дәүләт дип күзаллыйлар, чынлыкта исә бу һич тә алай түгел. Русия — үзе аерым бер дөнья, ул бары тик бердәнбер кешенең генә ихтыярына, рөхсәтенә, фантазиясенә күндәм. Әлеге кешенең исеме Петрмы, Иванмы, хикмәт анда түгел, һәр очракта да бу — башбаштаклык һәм законсызлык гәүдәләнеше. Кешелек яшәешенең барлык законнарына капма-каршы рәвештә, Русия бер генә юнәлештә — күрше халыкларны үзенә буйсындыру юнәлешендә генә бара. Шул сәбәпле аны башка халыклар мәнфәгатьләрендә генә түгел, үз мәнфәгатьләрендә дә бүтән юлларга күчәргә мәҗбүр итү файдалы булыр иде». Башбаштаклык — Русияне аңлау өчен кирәкле төп сүз шушы.

Урыс фикере үсешендә нигилизм өстенлек алган чор булган. Нигилизм бөтендөнья кыйммәтләрен кире кага, бөтен нәрсәгә дә шөбһәчел карый, ул атеизмны тудыра, әмма анда хакыйкать эзләү чаткылары да күп

була. Бүген аны урыс психологиясенә хас нәрсәгә — кимсетелгән һәм изелгәннәргә карата мәхәббәткә һич тә исе китмичә, ярлыларны ахмаклар дип атый торган цинизм алмаштырды. «Акыллы икәнсең, нигә болай ярлы соң син?» Теләсә нинди юллар белән җыелган акча егетлек билгесенә әйләнде. Кайчандыр карьерадан, матди байлыклардан баш тартып халык арасына аның культура дәрәҗәсен күтәрергә, тормыш хәлен яхшыртырга киткән урыс кешеләре булган. Бүген аларны акылдан язган дип санарлар иде. Хәзер үз халкыңны теләсә нинди — законлы яки законсыз юллар белән талау гадәти хәл булып санала. Һәм болар барысы да базар дип, демократия һәм либераллык дип атала. Ирек төшенчәсен кеше фантазиясе булдыра алган иң оятсыз кимәлдә шәрехләделәр.

Русиядә азмы-күпме йогынтылы либераль идеология беркайчан да булмаган. Ирек-хөрлек турында күбрәк анархистлар сөйләп килгән. Баш күтәрү — Русиягә һәрчак хас нәрсә һәм ирекне биредә күбесенчә анархия дип аңлаганнар. Үзенә кадәрге мәдәниятне җимерә торган урыс революцияләренең үзенчәлеге дә нәкъ менә шуннан килеп чыга. Европадагы буржуаз революцияләр яңа мөнәсәбәтләр тудырып, элеккеге культураны саклап, алга таба адым ясатканнар. 1917 елгы урыс революциясе исә алга да, артка да илтмәгән, илне бөтенләй башка үлчәмгә генә күчереп куйган. Идеологик яктан бу анархия күренеше булып чагылган. Бакунин һәм кенәз Кропоткин үзләренең дәүләтсез коммунизм идеяләре белән дөньяны дер селеткәннәр. Алар дәүләтне — җәмгыятьнең төп дошманы, ә бюрократчылыкны исә шәхес дошманы дип санаганнар. Бакунин язуынча, түрә кәнәфиләренә фәрештәләрне утырткан хәлдә дә, тиздән аларның канатлары урынына иблис тояклары үсеп чыгачак. Бакунин дәүләтне Алла идеясенә бәйләгән, ә Алла идеясен кешелек акылыннан, гаделлектән һәм иректән баш тарту дип бәяләгән. «Әгәр дә Алла бар икән, кеше — кол». Янәсе, Алла үч алучан, барлык диннәр дә рәхимсез. Алла — дәүләтнең залим формаларын аклау. Үзенең бер хезмәтендә ул, Христос чын-чынлап була калса, аны үтерү ярар иде, дигән. Бу — куркыныч фикерләр, ләкин анархистлар күпчелек очракта күрәзәче булып чыктылар бит. Бакунин фараз кылганча, әгәр дә берәр халык үз илендә марксизмны гамәлгә ашырырга тырышып карый икән, бу дөнья тарихында иң куркыныч тиранлык булачак. Сүз уңаеннан, коммунистлар да Алладан баш тарттылар, тик шуңа да карамастан явыз дәүләт төзеделәр. Бүген анархия идеяләре ни белән алмашынды соң? Башбаштаклык белән. Югарыда да башбаштаклык, түбәндә дә башбаштаклык. Бакунин белән Кропоткин аңындагы анархизм башбаштаклык булмаган, ул җәмгыятьне түрәләрдән башка оештыру, ягъни чын коммунизм булган. Кеше шул рәвешчә генә ирекле була ала дип санаганнар алар.

1993 елда, Русия Президентының Парламент белән капма-каршылыгы шартларында, Ельцин Парламентны аттырды, ә халык исә моңа әллә ни ризасызлык белдермәде. Юкса чып-чын башбаштаклык иде бит бу. Президент Явыз Иван яки император Петр I кебек эш итте: «Без үз холопларыбызны яратырга да ирекле, җәзалап үтерергә дә ирекле». Әмма иң куркынычы шунда ки, халык моңа түзеп калды, чөнки аның психологиясе империя тарафыннан салынган, ягъни бу — башбаштаклыкка түзә һәм аны аклый торган коллык психологиясе. Телевизор караучылар Ак йортка ату күренешен ниндидер бер сәяси тамаша караган кебек кухняда чәй эчә-эчә күзәттеләр. Моннан соң әле күп вакыт та узмады, әмма бүген бу вакыйганы шунда һәлак булган кешеләрнең туганнары һәм якыннары гына хәтерли инде. Теләктәшлек тә юк, ризасызлык белдерү дә юк.

Урыс философы К.Леонтьев раславынча, үзәкләштерелгән көчле хакимиятле урыс дәүләтчелеге татар һәм немец элементлары ярдәмендә булдырылган. Аның фикеренчә, урыс халкы һәм, гомумән, славяннар анархиядән башка берни дә кора алмаган булырлар иде. Шулай да урыслар әле Петр I чакырып китергән немецларга чаклы һәм Екатерина II гә кадәр үк территорияләрне колонияләргә әйләндерү белән мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнгәннәр, гәрчә татарлар таптаган юл белән барсалар да. Шул рәвешчә, анархизм өчен генә түгел, империя өчен дә урыслар үзләре җаваплы. Шулай да Русиядә империя идеясенең, мөгаен, Чыңгыз хан мирасы булганлыгын танырга кирәк. Әлбәттә, бөек Чыңгыз хан башбаштаклыкка юл куймаган, ул үз законнарын — «Бөек Яса»ны керткән, ә ханнар хакимияте дүрт бәк һәм корылтай системасы белән чикләнгән. Әмма хан ихтыярын закон дип игълан итү, ә корылтайны (соборны) җыймау әллә ни кыен түгел, һәм Петр шулай эшләгән дә.

Достоевскийның даһилыгы дөньяны көч кулланып берләштерүне кире кагуда. Ул авторитар христианлыкны да, авторитар социализмны бер үк дәрәҗәдә кабул итмәгән. Югары гармониягә көч кулланып ирешү мөмкин түгел. Иван Карамазов болай ди: «Югары гармониядән тулысынча баш тартам. Ул җәберләнгән бердәнбер баланың бер тамчы күз яшенә дә тормый». Бернинди изге максатка да кешене кимсетү исәбенә ирешелергә тиеш түгел. Кеше корбаннарын бернинди сәясәт тә аклый алмый. Әмма XX гасырда барысы да киресенчә булып чыкты. Достоевский күпкә алдан, фашизм барлыкка килгәнче үк, аның психологиясен аңлаган. «Бөек Инквизитор»да мондый юллар бар: «Гомуми табыну аркасында алар бер-берсен кылыч белән үтергәннәр. Алар аллалар барлыкка китереп, бер-берсен: «Аллаларыгызны ташлагыз һәм безнең аллаларга табыныгыз, югыйсә үзегезгә дә, аллаларыгызга да үлем киләчәк!» — дип өндәгәннәр. Дөнья бет-

кәнче, хәтта дөньяда аллалар юкка чыккач та шулай булачак: потларга баш иячәкләр... Сиңа әйтәмен, адәм баласының үзе белән туган иреген тизрәк илтеп бирер өчен кемне дә булса эзләп табудан да зуррак гаме юк. Әмма кешеләрнең ирегенә аларның намусын тынычландырган кеше генә ия була». Фашизм кеше ирегенең киңәюенә, кешедә чиктән тыш җаваплылык барлыкка килүгә җавап булды, кеше, ул җаваплылыктан качып, вөҗдан тынычлыгын хакимияткә буйсынуда тапты. Ул мәгънәлелек кыяфәте тудыручы һәм тәртип кертүче теләсә нинди идеологияне, теләсә нинди сәяси төзелмәләрне һәм символларны кабул итәргә әзер. Ирекле булу хисе кешене бөтереп ала һәм ул иректән качып диктатура канаты астына да керергә әзер. Бу феноменны Эрих Фромм «иректән качу» дип атаган. Бу — кешенең эчке фаҗигасе, ул ирекkә омтылышның үз эченә үк салынып куелган. Инде Аристотель үк күреп алган: кешеләрнең күбесе — табигатьләре буенча коллар, әгәр дә аларның чылбырларын салдырсаң, алар үз гамәлләренең киң мөмкинлекләрен үз кулларына ала алмыйлар, аларның үз гамәлләре өчен җаваплылыкны үз өсләренә алыр өчен әхлакый көчләре юк, шуңа күрә алар ул җаваплылыкны кемгәдер йөкләргә омтылалар. Гитлер Германиясе һәм Сталин СССРы Аристотель һәм Достоевский фаразларының дөреслеген раслады.

Кеше һәм дәүләт проблемалары, дин белгечләре бәхәсләре, сугышчан атеизм, халыкчылык (народничество), монархизм һәм социализм, террор, анархизм һәм эстетик символизм... XIX гасырда урыс фикриятендә темалар искиткеч күптөрле һәм аларның һәрберсендә бөек исемнәр калкып чыккан. Ә менә XX гасыр уртасында — кинәт өзеклек һәм XXI гасырда — кызганыч бытылдау. Бүген үткән заманның бөек әсәрләре белән рәттән куярлык нәрсә юк. Солженицын — күренекле язучы, ләкин Бердяев һәм Трубецкой, Чехов яки Шолохов янәшәсендә ул бары тик күләгә генә. Солженицын үзенең Русияне коткару хакындагы фикерләре белән хәтта ачуны да китерми, ул — кызыксыз. Кызыксыз! Аның бар пафосы абстракт өндәүләргә кайтып кала: «Хәзерге дәүләткә түгел, Ватанга хезмәт итәргә. Ватан — безне барлыкка китерүче. Ул — өстенрәк, үзгәреп торучы төрле конституцияләрдән югарырак. Русиянең хәзерге күптөрле тормышы ничек генә төшенке булмасын — безнең әле ныгырга һәм үзебезнең 1100 еллык җуелмас үткәнебезгә лаеклы булырга вакытыбыз бар. Ул — безгә кадәрге һәм бездән соңгы дистәләгән буыннар казанышы». Русиялеләрнең хәзерге һәм киләчәк буыннарына тарихи юллама роленә дәгъва кылучы әлеге үгет-нәсихәтләрдә ниндидер фикер бәян итәргә тырышу да юк хәтта.

Детектив — Пушкинны һәм Тургеневны, «сабынлы опералар» Чеховны һәм Островскийны алмаштырды, вак «попса» Мусоргскийның бөек музыкасына алмашка килде. Дәүләтчелек үсеше даирәсендә идеяләр бөтенләй юк. Либералчылыктан — «хакимият вертикаленә», ялган федерализмнан ялган империягә ташлану бара. Фәндә исә үткән еллардагы темалар уйнатып бетерелә. Нобель премиясенең Русиядәге яңа лауреатлары — безнең көннәргәчә яшәгән карт совет галимнәре. Урыс рухы сүнгәнгә охшап тора. Моның нинди куркынычы бар соң?

Болар барысы да — «каһәрләнгән» сораулар. Татар рухы да сүнгән, урыс рухы да сүнгән... Тирә-якта барысы да бөек Русиянең яңаруы турында сөйләп торганда мондый сораулар куяю отышлы түгел, әлбәттә. Әмма дәүләт бөек булса да, инде үткән заманда калган мәдәният турындагы истәлекләр белән генә яши алмый лабаса. Халык киләчәкне тарихи үрнәкләр буенча гына төзи алмый.

XX гасыр ахырында Русиянең хәлләре мөшкел иде. Дәүләт шигрин күне сыман кечерәя башлады. Иң элек Польша һәм Финляндия аерылып чыкты. СССРны таратканнан соң «Зур Русия» таркалды. Хәзер Украина һәм аның белән бергә Кырым һәм Кара диңгез китте. Көньяк өлеш Оренбург далаларына якынайды. Балтыйк буе берничә дәүләт арасында калды. Русия Петр чорына кадәрге чикләргә кире кайтты. Русия составында урыслар кабат татарлар белән йөзгә-йөз калдылар һәм Мәскәү каршына «Казан мәсьәләсе» кабат килеп басты. XVI гасырдан башлап Русия идеологиясе «Казан мәсьәләсен» хәл итү зарурлыгына нигезләнде, өстәвенә күбесенчә көч кулланып. «Мәскәү патшалыгы үсешенең табигый өлеше булып «Казан мәсьәләсен» хәл итү, ягъни көнчыгышта илнең мөһим үзәкләренә янау сәләтенә ия булган соңгы куркыныч каршылыкны бетерү һәм урысларга чиксез булып тоелган көнчыгыш пространствога: далаларга, тайгага, тундрага, океаннарга бәреп керү тора»,— дип яза В.Цымбурский. Русиянең тарихында һәм сәясәтендә Казан белән Мәскәү арасында мөнәсәбәтләр аерым, билгеле бер дәрәҗәдә символик мәгънәгә ия. Русияне Киевтан башка күзаллау мөмкин, әмма Казаннан башка күз алдына китереп булмый. Мондый тезис бары тик беренче карашка гына парадокс кебек күренә.

Киев рәсми идеология буенча Русия дәүләтчелегенең башлангычы булып санала, ә хәзер исә ул — чит ил. Әгәр Киев — «урыс шәһәрләренең анасы» — бәйсез дәүләт башкаласы икән, хәзерге Русиянең тамырларын Киев Русеннан эзләү ни дәрәҗәдә мөмкин соң? Бу Русия тарихын рәсми шәрехләүнең ялгыш икәнен күрсәтә түгелме? Инде шулай да Киев Русе чынлап та хәзерге заман Русиясенең башлангычы икән, ул вакытта Русия дәүләтенең Украинасыз дәүләтчелек феноменын ничек аңлатып була? Бу очракта «дәүләтнең табигый чикләрен» (В.О.Ключевский атамасы) билгеләүче генетик тамырлары кайда? Дәүләтнең тарихи биләмәләре үзләрен мөстәкыйль милләт дип игълан итеп, җиңел генә яңа дәүләт ясый ала икән, бу дәүләт

тагын да кечерәймәсме? Әгәр Киев Русия түгел икән, Казан үзен шулай дип игълан итәргә тагын да хаклырак лабаса.

Тарих җиңелчә шәрехләүне яратмый. Чөнки бу бик күп дәгъваларны аклау булып чыга. «Русия Федерациясе Президентының Федераль җыенга милли куркынычсызлык буенча юлламасы» мондый юллар белән башлана: «Тарих күзлегеннән караганда, Русия — Борынгы Русь, Мәскәү патшалыгы, Русия империясе варисы, СССР дәвамчысы». Моннан чыгып дәүләтнең мөһим мәнфәгатьләре турында тирән нәтиҗәләр ясарга һәм эчке генә түгел, тышкы сәясәтне дә төзергә мөмкин. Бүген Русиянең килеп чыгышын Киевтан башка бәян итү җиңел түгел — бик күп нәрсәне кабат язарга туры киләчәк. Күпләргә илнең яңа чикләре эчендә үсеш юллары эзләүгә караганда Украина һәм Белоруссия белән кабат берләшү җиңелрәк тоела.

Тарихи үзаң — иҗтимагый кыйммәтләрне бер җепкә беркетүче элемент. Күп очракта Русия халыклары урысларга караганда борынгырак тарихка ия. Бүген һәрбер халык үз тарихын мөстәкыйль яза. Ә бөтен илнең тарихын нидән башларга соң? Төрки, Хәзәр, Авар каганлыкларыннан, «Дәшти Кыпчак»тан (Кыпчак далалары), Болгар патшалыгыннан һәм башка борынгы халыклар тормышыннан икән, димәк, Русияне полиэтник дәүләт дип танырга кирәк? Яисә, урыс булмаган халыкларның яшәешен төшереп калдырып, Русия тарихын саф урыс тарихы дип шәрехләргәме? Бу — гыйльми мәсьәлә булудан бигрәк сәяси мәсьәлә. Ул җәмгыятьнең асылына кагыла һәм халыкның үз-үзен ничек атавына бәйле. Чынлап та, Русия язмышы өчен кем җаваплы? Урыслармы? Русиялеләрме? Күпмилләтле халыкмы? Территорияләр кушылмасымы? Әгәр дә дәреслекләр татар тарихын объектив бәян итмәсә, татар халкы илнең кыйммәтләре системасыннан читтә калачак.

Казан белән Мәскәү арасындагы мөнәсәбәт хәзергәчә үзенең фундаменталь әһәмиятен саклый. Бу күчәр нык булганда илнең киләчәген күзалларга мөмкин. Әгәр дә ул күчәр какшаса, үзәктән куучы көчләр барлыкка киләчәк. Әлбәттә, сәяси күзлектән караганда, Русия һәм Татарстан — капма-каршы куела алмаслык күренешләр. Русия гасырлар буена Европа һәм дөнья сәясәтендә төп рольне уйнап килә. Аның җитәкчеләре телеэкраннардан төшми, газеталар көн саен аның эчке һәм тышкы сәясәте турында яза, дистәләгән халыкара үзәк, Русиянең алга таба ни кыласын фаразларга тырышып, аны һәрьяклап тикшерү белән мәшгуль.

Татарстан исә — бөтенләй башка мәсьәлә. Күпчелек кеше өчен ул гасырлар төпкелендә югалып калган. Европа үзаңына ул Чыңгыз хан, «Тартария»нең иксез-чиксез кыргый киңлекләре, татар-монгол явы, Азия эчендә яшәгән күчмә халыклар турындагы ниндидер тонык күзаллауларга бәйле рәвештә кереп калган. Республика турында бары тик тарих белгечләре, этнографлар, Татарстанга килеп киткән журналистлар гына яздылар, болары да, нигездә, Казан белән Мәскәү арасында мөнәсәбәтләр кискенләшкән чорларга туры килә.

Русия иксез-чиксез территория биләп тора, Татарстан исә — зур булмаган республика, аның халкы да бик күп түгел. Урыс мәдәнияте бөтен дөньяга билгеле, татар мәдәниятен хәтта Русиядә дә белмиләр. Чынлап та, Русия белән Татарстан төрле «көч категориясендә», аларны чагыштыру да кыен. Гаять зур Русия белән халкы 4 миллионнан кимрәк, өстәвенә катнаш халыклы, илнең эчендә урнашкан кечкенә территорияле Татарстан арасында җитди бәхәс туу мөмкинлеге турындагы фикер күпләргә хәтта көлке сыман. Нинди бәхәс була алсын инде биредә! «Мәскәүдән Татарстан күренми. Күренми!» Аны губерна итәргә кирәк һәм вәссәлам! Әмма зирәк сәясәтчеләр Татарстанга башкача карыйлар, алар Давид һәм Голиаф турындагы Библия риваятен яхшы хәтерлиләр һәм тота-каба нәтиҗә ясарга ашыкмыйлар.

Русия белән Татарстан кабат тарих чатында. Мөмкинлекләр тигез түгел, әмма бу — замана тудырган вазгыять.

Сүздә генә бөек булган, уйлап чыгарылган Русия түгел, чын Русия алга таба нишләр? Татарларның урыны кайда булыр? Алар бит хәзер юклыктан чыктылар һәм яңадан сәяси факторга әйләнделәр. Вазгыять шул дәрәҗәдә үзгәрер дип кем уйлаган? Хәзер Русия язмышы өчен урыслар гына түгел, татарлар да җавап бирергә тиеш була. Моңарчы андый бурыч куелмаган иде. Моңарчы культураны, телне тергезергә, үз хокукларыбыз өчен көрәшергә, империянең астыртын ниятләренә каршы торырга, Татарстанны ныгытырга кирәк иде, хәер, боларны бүген дә дәвам итәргә кирәк, әмма шул ук вакытта Русия дәүләтчелегенең татарлар язмышы белән ярашу мәсьәләсе дә бар. Русия зәгыйфь булган хәлдә татарларның иминлеген күз алдына китерү дә кыен. Татар халкы киләчәге өчен Татарстан берүзе генә җавап бирә алмый, чөнки татарлар бөтен Русия буйлап яши, ахыр чиктә, кемнәргәдер бу сүзләр ошамаса да, Русия территориясе — ул элеккеге Төрки каганлык, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары, Зур һәм Нугай Урдасы биләмәләре. Бергә бары тик Кырым ханлыгы гына җитми.

Урысларны һәм татарларны күп нәрсә берләштерә: тарих, антропология, психология. Лев Гумилев раславынча, урыслар һәм татарлар — бердәм этнос, бары тик берәүләр православие, икенчеләре ислам юлыннан киткән. Ләкин аермалыклар да күп: дәүләткә, җәмгыятькә, гаиләгә, җиргә, хезмәткә мөнәсәбәттә.

Урыс кешеләре һәрвакытта мәхәббәтне һәм хакыйкатьне гаделлектән өстенрәк күргәннәр. Закон буенча түгел, намус кушканча яшәргә, «Царство Небесное» һәм «Град Грядущий»ны эзләргә. Татар традицияләрендә исә «тугры юл» — законнарны һәм кагыйдәләрне үтәү, һәм, әлбәттә, гаделлек буенча яшәү. Гадел исеменең татарлар арасында популяр булуы да шуннан килә. Казандагы урта гасырлар шагыйре Мөхәммәдъяр болай дип язган:

Бер сәгать гадел кыйлмак яхшырак,
Кем гыйбадәт алтмыш елдин азрак.

Татар тарихында дәүләт проблемалары килеп чыгу гаделлектән тайпылу дип аңлатылган, гаделлек төрки каганлыклары чорыннан ук идарә итүнең иң мөһим шарты булып саналган.

Төрки хакимиятенең парадигмасы мондый булган: Бодун — Әл — Тора (Халык — Дәүләт — Закон). Урысларның күпчелеге дәүләтне яратмый, хакимиятне ихтирам итми. Татарлар — дәүләтчеләр. Хәтта үзләрен изгән, кимсеткән, хокукларын чикләгән урыс дәүләтен дә татарлар урыслардан ныграк ихтирам иткәннәр. Татарларга элек-электән үк бунтарьлык хас түгел, ә Пугачев һәм башка восстаниеләрдә катнашулары көчләп христианлаштыруга каршы ризасызлык белдерү булган. Татарлар җир эшкәртүне, торак төзүтөзекләндерүне өстенрәк күргәннәр. Бездәге «нигез» төшенчәсе үз җиреңдәге йорт мәгънәсеннән күпкә тирәнрәк. Бу — ата-бабалар культы, үз тамырларың, чишмә башы турында истәлек. Татар кешесе белән очрашып танышсаң, хәтта бер шәһәрдә, бер урамда яшәсәң дә, шунда ук бер-береңнең туган җире турында сораша башлыйсың. Һәм, Казанда туып гомер буе Казанда яшәсәң дә, килеп чыгышың буенча Казан артыннан, Күлле-Киме авылыннан булуың турында сөйләп бирергә тиешсең. Моңа җавап итеп әңгәмәдәшеңнең ата-бабалары кайдан булганлыгын ишетәсең. Татарлар үз туган җирләренә, үз тамырларына нык бәйләнгән. Бу әдәплелек кенә түгел, бу — тулы бер фәлсәфә.

Урысларда мөсафирлык психологиясе өстенлек итә, алар хәрәкәтчән, үзләре яшәгән авыллардан яки шәһәрләрдән җиңел күчеп китәләр, яңа урыннарга да җиңел җайлашалар. Бу даими рәвештә күнегергә, җайлашырга кирәк булган яңа җирләрнең бик күп булуыннан килә, күрәсең.

Бүгенге глобальләшү чоры бик күп тотрыклы күзаллауларны җимерде, бөтен дөньяга уртак кыйммәтләрне һәм уртак психологияне көчләп тага башлады. Дөньяны экстерриториаль рәвештә кабул итү һәм хәрәкәтчәнлек өстенлекле фактор булып бара. Америкалы, европалы яки кытайлы өчен эшчәнлек киңлеге — бөтен дөнья. Алар үзләрен номадлар — урта гасырлардагы күчмә халыклар кебек тота башладылар, чөнки базар — уртак, акчалар бөтен дөнья буйлап тулысынча иреклe рәвештә йөри, яшәү урынына бәйләнгәнлек юк, ә үзара аралашу чаралары ерак араларны якынайтып, бөтен дөньяга юл ачтылар. Планета бердәм киңлеккә әверелде. Глобальләшү бар кешеләрне дә төрле илләрнең мәнфәгатьләре белән яшәргә, төрле континентлардагы фаҗигаләрне бергәләп кичерергә, космонавтларның уңышлы очышларына бергәләп шатланырга, Айның һәм Марсның ландшафтларын игътибар белән күзәтеп барырга мәҗбүр итеп, фикер йөртү рәвешен үзгәртә. Сәясәт, икътисад һәм культура әверелешләре бара. Инде мәңгегә тарихта калган күчмә халык культурасы кире кайткан кебек тоела, Чыңгыз ханның һич югалмас рухы — экспансия рухы кабат яңара, әмма бу юлы ул англо-саксларга күчә.

Урыс акыл ияләренең иң күренеклесе Николай Бердяев болай дип язган: «Халыклар тормышында тотрыклы яшәп килергә мөмкин ике миф бар. Аларның берсе — килеп чыгыш турында, икенчесе — ахыргы көн турындагы миф. Урысларда ахыргы көн турындагы миф — эсхаталогик әкият өстенлек итә». Ә татарларда исә ни килеп чыгыш турында, ни ахыргы көн турында мифлар юк. Татар тарихының башы турында төрле уйдырмалар барлыкка килгән үзе, иң уңай очракта аны татарлар килеп чыгышының чикле-территориаль «болгар» концепциясенә кайтарып калдыралар, тискәре очракта — Алтын Урда һәм татар ханлыклары чорларына яла ягып, аларны кыргыйлар дип атыйлар. Киләчәк турында миф исә милләтләрнең кушылуы «теориясенә» кайтарып калдырыла, анда татарларга «табигый рәвештә» юкка чыга баручы халык язмышы билгеләнә. Әмма мең еллар сакланган рух эзсез югала алмый. Ул яңаруны көтә, ул яңа биеклекләргә омтыла, ул яңа әверелешләргә әзерләнә, ул кискен үзгәрешләр көтеп үзенә тартып тора. Яңа меңьеллык яңа геройлар таләп итә. Татарлар заман чакыруына ничек җавап бирерләр микән?

Хәер, сораулар җитеп торыр, җаваплар эзлик.

## «Рәхимсезлек»

*Күпсанлы килеш алар бер-берсе белән дошман булмыйча бердәм булсалар, кытайлар һәм башкалар арасыннан бүтән халыклар һәм, гомумән, беркем дә аларга каршы тора алмас иде. Әмма шулай да араларында дошманлык һәм ызгыш-талаш хакимлек итүгә*

*дә карамастан, алар бик борынгы заманнардан ук күп вакыт кабиләләрнең һәм өлкәләрнең иң зур өлешен буйсындыручылар һәм хакимлек итүчеләр булганнар, үзләренең бөеклекләре, куәтләре һәм башкалар ихтирамын казанулары белән аерылып торганнар. Аларның гадәттән тыш бөеклеге һәм югары абруе аркасында башка төрки кавемнәр, төркемнәре һәм исемнәре төрле-төрле булуга карамастан, дөньяга шулар исеме белән билгеле булганнар һәм барысы да татарлар дип аталганнар.*

Рәшидетдин. «Җәмигъ-әт-тәварих»

Дөнья үзаңында татарлардан яшерен бер курку калган, ул куркуны Батый ханның Европага басып керүе тудырган. Аңа татар-монголларның «рәхимсезлеге» турында әкиятләр чәпәлгән. Алдан ук туган ялгыш фикер «кыргый татарлар» һәм беркем күрмәгән-белмәгән куркыныч «Тартария» турында легендалар китереп чыгарган. Папа Иннокентий IV 1234 елда: татарлар «Иблис илчеләре һәм Тартарус ялчылары»,— дип язган, аларга каршы тәре походы игълан иткән. Шул заманнардан алып татарларны цивилизациягә каршы кую гадәткә кергән. Әле соңгы елларга кадәр Европаның католик храмнары вәгазьләрендә Алладан тәмуг кисәүләре — татарлардан коткаруын сорыйлар иде. Бөтен бер халык уртаклык исемгә — «татарщина»га әверелде. Бу әкиятне Лев Гумилев «кара легенда» дип атады.

Татарларның урынлы-урынсыз искә алына торган «рәхимсезлеге» үз дәвере кысаларыннан чыкмаган һәм һәрвакыт Чыңгыз ханның «Бөек Яса — Ясак» (законнар кодексы) белән чикләнгән. Урта Азиягә поход вакытында Чыңгыз ханның кияве темник Тогучар үзенә каршылык күрсәткән бер шәһәрнең халкын рәхимсез җәберләгән. Чыңгыз хан, бу турыда ишетеп, чыгырыннан чыккан һәм бары тик бераз тынычлангач кына киявенең үлем җәзасын гади сугышчы дәрәҗәсенә төшерүгә алмаштырган. «Яса» бөек хан ихтыярына буйсынучы шәһәрләрнең, халыкларның, илләрнең куркынычсызлыгын тәэмин иткән. Ул башбаштаклыкка юл куймаган. Шунысын да әйтергә кирәк, ул урынсыз мәрхәмәт өчен дә җәза биргән.

Рәхимсезлек татар-монгол яуларының принцибы да, аларга хас сыйфат та булмаган һәм чыңгызчылар тарафыннан хупланмаган да. Чыңгыз ханның уллары Җүчи һәм Үгәдәй игелекләре һәм сабырлыклары белән аерылып торганнар, ә Чыгытай исә таләпчән, эшне төгәл башкаручан һәм хәтта кырыс булган, шуңа күрә «Ясаны саклаучы» вазифасы (прокурор эшенә охшаш гамәл) аңа йөкләнгән. Елъязма мәгълүматлары буенча, Батый хан, үз сугышчыларына карата таләпчән булса да, Урта Азия кампаниясендәге чамадан тыш рәхимсезлекне гаепләп чыккан.

Каршылык күрсәткән шәһәрләрнең халыклары, балалар һәм хатын-кызлардан, рәссамнардан, һөнәрчеләрдән һәм, гомумән, нинди дер гыйлемгә ия кешеләрдән тыш, гадәти кыйнауга дучар ителгән. Баш күтәргән шәһәрләргә һәм өлкәләргә карата аяусыз террор кулланылган, аеруча гаскәрләр тылында, чөнки татар-монголлар, аз санлы булу сәбәпле, кальгаларда гарнизоннар тота алмаганнар. Бу хәрби зарурлык булган.

Террор — барлык заманнарда да сугыш алып баруның бер ысулы. Викинглар походлары турында укыганда, мәсәлән, аларның чиксез-чамасыз талауларыннан котың алына, елъязмачылар алар хакында «бүреләр кебек котырыналар» дип язып калдырганнар. Андрес Стриннгольм викингларның Англиягә походы турында болай дип язган: «Алар терлекләрне алып китteләр, чиктән тыш кансызлык күрсәтеп таладылар, кеше үтерделәр, руханиларны да, монахларны да, монах хатын-кызларны да бервакытта да аямадылар». Викингларның Франциягә, Италиягә, Сицилиягә һәм башка илләргә һөҗүмнәрен дә ул шулай тасвирлый. Викинглар үз походларына сагаларда дан җырлаганнар. Аларның берсе, Рагнар Лодброк исемлесе, үләр алдыннан мондый җыр җырлый: «Без илле бер сугышта кылыч белән кеше кырдык. Кешеләр арасында миннән дә данлырак король бар микән? Мин яшьтән үк кан койдым һәм шушындый үлем теләдем. Один илчеләре валькирияләр, миңа дәшәләр, мине чакыралар; мин мактаулы урында аллалар белән сыйланырга китәм. Минем гомерем бетеп бара, әмма мин елмаеп үләм». Ул юлбасар буларак тотылган һәм үтерелгән, шул ук вакытта ул елмаеп үзенең рәхимсезлеге турында җыр җырлый.

Татарлар Муса Җәлил җитәкчелегендә Моабит төрмәсендә (моны үзе күреп торган патер Юрытко әйтүенчә) елмаеп үлгәннәр. Әмма алар елмаюның мәгънәсе булган. Совет әсирләре арасында бары тик татарлар гына үз ватандашларына атмаганнар — әсирлектә оештырылган бер генә татар полкы да фашистлар ягында сугышмаган. Муса Җәлил болай дип язган:

Ил онытмас, бирсәң каныңны
Ватан өчен изге көрәшкә.
Хаин каны тама чиләккә,
Батыр каны тама йөрәккә.

Батыр үлә, үлмәс ат алып,
Батырлыклар белән макталып.
Исмең калсын, үзең үлсәң дә,
Тарихларда укып ятларлык.

Бу инде бөтенләй башка төрле сага...

«Бөек» викинг Сокке Халогаландка — зур булмаган Ульфей утравына килгән. «Биредә,— дип әйткән ул иптәшләренә,— без шәп табыш алачакбыз, чөнки монда бай кеше яши; аның йортына кылыч һәм ут белән һөҗүм итәрбез; бөтен хуҗалык безгә булыр, ә йортларны һәм кешеләрне яндырып үтерербез». Һөҗүмгә дучар ителгән Ульфей кешесе викинглар юлбашчысыннан, ни өчен болай җәберлисез, дип сораган. «Без, викинглар, берәрсенең җанын яки мөлкәтен алырга теләсәк, ни өчен дип сорамыйбыз»,— дип җавап биргән ул. Викингларның талаулары турында йөзләгән, меңләгән җыр чыгарылган. Алар беркемне дә аямыйлар, монастырьлардан, храмнардан башлап барысын да тоташ бөлдерәләр, алар мәкерлегенең чиге юк, ләкин без шведлар, норвегияleләр һәм данияleләр хакында башка батырлыкларына карап фикер йөртәбез. Нигә соң татарлар турында ялган мифларга карап фикер йөртәләр?!

Сугышлар гына түгел, революцияләр дә террорсыз гына узмаган. Якобинчылар диктатурасы үтә рәхимсез булган, гильотина бер дә туктап тормаган. Дәүләт терроры идеясе үзе үк Робеспьер режимы тарафыннан тудырылган. Ул, Дантонны җәзалап үтереп, революциянең тигезлек һәм гаделлек идеалларына ышанычны кабергә салган. Моның белән Русиядәге Гражданнар сугышы һәм 1937 елгы репрессияләр генә тиңләшә ала, шуңа да карамастан француз революциясен «Бөек» дип атыйлар.

Октябрь революциясе вакытындагы «кызыл террор» миллионлаган кешенең гомерен өзгән, колачы ягыннан ул татар-монгол яуларының Евразиянең барлык почмакларында өч йөз ел эчендәге корбаннары саныннан да бик күп мәртәбәләр артык. Гильотинаны да татарлар түгел, мәгърифәтле французлар уйлап тапкан, Бухенвальд мичләрен дә немецның «явыз даһие» уйлап чыгарган. Ә Хиросимага атом бомбасын мәгърифәтле американлылар ташлады. Әмма без бу халыкларга аларның башка казанышларына карап бәя бирәбез, алар уйлап тапкан әйберләрнең асылы — варварларча, кулланылуы иезуитларча булып, цивилизация казанышларын халыкларны кыру өчен кулланылсалар да, без аларны кыргый дип атамыйбыз. Цивилизация белән кыргыйлык арасындагы чик каян үтә соң алай булгач?

Урта гасырлар, гомумән, гуманлы дәвер булмаган. Тынычлык сөю уңай сыйфат булып саналмаган. Тәре походлары, Европаны япан чүлгә әйләндергән 30 еллык сугыш афәте, коточкыч рәхимсез инквизиция! Ә конквистадорларның Көньяк Америкага, инклар, ацтеклар һәм майялар алтынын кулга төшерү өчен башлаган походлары гына ни тора! Алардан соң бөтен-бөтен илләр һәм цивилизацияләр юкка чыккан. Казанны басып алу яки татарларны христианлаштыру вакытындагы рәхимсезлекнең иге-чиге булмаган. Мәгънәсезлеге, нигезсезлеге, чиксезлеге ягыннан Явыз Иванның кансызлыгына берәү дә тиңләшә алмас, мөгаен. В.О.Ключевский Новгород шәһәрен күздә тотып язганча, Явыз Иван «берни дә тикшереп тормыйча, шикләнү нигезендә генә, тик кенә, болай гына борынгы зур шәһәрне бөтен бер өлкәсе белән бергә кансыз, оятсыз рәвештә тар-мар итте, татарлар бервакытта да бер генә урыс шәһәрен дә болай җимермәгәннәр». Нәтиҗәдә, Бөек Новгородта 6000 хуҗалыктан бары тик 1000 хуҗалык кына торып калган. Мәскәүдә Явыз Иван тәмам азып киткән һәм чып-чын террорга күчкән. «Патша җәбере, сөргеннәр, шикле кешеләрне җәзалап үтерүләр, опричникларның «сатлыклар»га карата көч куллanулары, оргияләр вакытында үз кешеләрен рәхимсез газаплаучы Явыз Иванның чиктән тыш азгынлыгы — болар барысы да Мәскәүнең тиран алдында калтырап торуына һәм колларча басынкылыгына китергән»,— дип яза С.Ф.Платонов. Петр I нең походларын да тыныч походлар дип атап булмый. Атаклы генерал Ермолов та Алтын Урда заманнарыннан ук Мәскәүнең тугры аркадашы булган нугай халкын, хәрби яктан максатка ярашлы дигән булып, тоташ суеп чыккан. Тарихчылар моны искә алырга яратмыйлар.

Тарих — рәхимсез сугышларның һәм кансыз режимнарның тоташ чылбыры. Александр Македонский каршылык күрсәткәннәре өчен күп шәһәрләрне тулысынча юкка чыгарган, Цезарь да Галлиядәге рәхимсезлеге буенча Македонскийдан калышмаган. Мәгърифәтле чорда яшәсә дә, Наполеонны да фәрештә дип атау кыен. Американлылар бөтен бер кыйтганың дистәләгән халыкларын кырып бетергәннәр, ә соңыннан боларның барысын да горур индеецлар һәм кыю ковбойлар турындагы романнарда һәм фильмнарда тасвирлап чыкканнар. Бүген төрле кыйтгалардагы балалар Чингачгук һәм кешенең баш тиресен салдыручылар булып уйныйлар. Тарихның хурлыклы сәхифәләре һәм сәер романтика. Европа романтикасы — мәхәббәт мажараларын, Америка романтикасы колониаль сәясәтне данлый. Тарихи бөжраларының шушы чылбырында татарлар үз урыннарын алганнар һәм рәхимсезлек белән түгел, ә бөтенләй башка сыйфатлары белән аерылып торганнар, әмма болары бары тик белгечләргә генә мәгълүм шул.

Карл Маркс урыс халкының җаны татар-монголлар тарафыннан «изелгән, бозылган һәм корытылган» дип саный, ләкин фактлар башка нәрсә турында сөйли: урыслар шушы «золым»нан соң бөек дәүләт төзиләр. Моны «бозылган һәм корытылган» җан белән эшләп буламы? П.Н.Савицкий сүзләрендә дөреслек күбрәк: «Чыңгыз, аның гаскәриләре һәм дәвамчылары күп рәхимсезлекләр кылганнар. Шулай да күчмә халыкларның экспансия рухы Европа колониализмына караганда сабыррак та, кешелеклерәк тә булган дип расларга җөрьәт итәм. Моңа меңләгән генә түгел, миллионлаган дәлил бар. Америкада испанлылар ниләр генә

кыланган! Ә португалиялеләр! Ә Ост- һәм Вест-Индиядә инглизләр! Африканы талау, гасырлар буе кара тәнле коллар белән сәүдә итү үзе генә дә ни тора! Алтын Урдада сабырлык рухы «Үзбәк патша басурманлашкач» та сакланып калган. Монгол державасы эчендә яңа Русь барлыкка килгән. Кешелекнең киләчәк язмышы тулысынча шуның белән билгеләнгән һәм билгеләнә түгелме икән?

Урта гасырларда кеше гомеренең бәясе хәрби максатка ярашлылыктан түбәнрәк булган. Хәтта XX гасырда да әлеге принципны дошманнарга гына түгел, үз кешеләренә карата да киң кулланганнар. II Бөтендөнья сугышы вакытында маршал Жуков Кенигсбергны алганда, бернинди хәрби максаттан да чыгып түгел, бары тик Сталинга бүләк ясау өчен генә уннарча мең иң яхшы совет солдатын шәһәр диварлары астына күмеп калдырган. Чыңгыз хан исә камалыштагы ныгытмаларны штурмлауга иң яхшы сугышчыларны түгел, әсирләрне куган. Әйе, кешелекле гамәл булмаган бу, әмма фашист концлагерьларының беренче үрнәкләре булып, Русия җәмгыятенең иң югары катламының уртак каберенә әйләнгән Сталин лагерьлары моннан нәрсәсе белән кешелеклерәк соң? Чыңгыз хан әле ул үзенең дә, дошманнарының да сугышчыларын, чиркәү кешеләрен, һөнәрчеләрен саклаган. Аның гаскәрендә һәм дәүләт хезмәтендә элеккеге әсирләр — гыйлем кешеләре, кәсеп ияләре күптин-күп булган.

Тарих бервакытта да кешелеклелектән газапланмаган. Каршылык күрсәтмәгән яисә чит биләмәләр яуламаган халык тарихтан төшеп кенә калган.

Русиядә хәзергәчә татарларны кешеләрне утта кыздыручылар итеп тасвирлаган китапларны бик теләп бастыралар. Югыйсә моның булуы мөмкин түгел, чөнки бу «Яса» законнарына каршы килгән, ә Монгол империясендә тәртип бик каты булган — законнарны бозган өчен аяусыз җәза, күбесенчә үлем җәзасы биргәннәр. Чынлыкта исә варварчылык тәре йөртүчеләргә хас булган ул, аларның тәртибе бернинди нормалар белән дә чикләнмәгән. Ач рыцарьлар учакларда балаларны кыздырып, кеше ашаучылык белән шөгыльләнгәннәр. 1099 елда алар Иерусалимда бер генә тере җан да калдырмаганнар, хәтта имчәк балаларын да үтереп бетергәннәр. Тәре йөртүчеләр яһүдиләрне һәм мөселманнарны гына түгел, үз христианнарын да, тыныч халыкны да үтергәннәр. Сату-хыянәт тә алар өчен гадәти хәл булган: «1260 елда, монгол-христианнар Фәләстыйнга, «Ходай Табутын» мөселманнардан азат итәргә баргач, андагы тамплиерлар (изге христиан ядкәрләрен яклаучы тәре йөртүчеләр ордены) мәмлүкләрне арыган монголларның тылына үткәргәннәр, ә мәмлүкләр сирияле һәм әрмән христианнарын үтерә башлаганнар. Тамплиерлар аларны яклап маташмаганнар. Алар башта Кипрга качканнар, соңыннан Европага ук кайтып киткәннәр. Европада аларга каршы шау-шу купкач, тамплиерлар бөтен гаепне монголлар өстенә өйгәннәр һәм җәмгыять каршында акланганнар. Вакытлар узгач шушы ялган орлыклары либераль тарих белеме җирлегендә шытып, XVIII гасырда көчле үсентеләр биргән, ул вакытта Европа Русиянең көчәюенә Монгол олысын тергезү дип караган. Шулай итеп, сатлык тамплиерларның җиңел кулыннан Европа тарих белеме татарларны, монголларны һәм урысларны каралта башлаган, шушы «кыргый азиатлар»га цивилизацияле һәм тәкъва Көнбатышны каршы куйган. Шул рәвешчә «кара легенда» башта Көнбатыш Европада, аннан соң бездә — Русиядә тамыр җәйгән, чөнки чынбарлык һәрвакыт әкияткә караганда авыррак кабул ителә». Ә хәзерге заман татарлары шушы яланы күтәрергә мәҗбүр, чөнки безнең тарих турында, нигездә, Европа һәм урыс авторлары язган, алар исә объектив мәгълүмат эзләп интекмәгән, газапланмаган, аларның каләмен алдан ук ялгыш караш йөрткән. Катып калган стереотиплар хәзергәчә телдән телгә күчә, һәм аларны абруйлы кешеләр авызыннан ишетү аеруча гарьләндерә. Чыңгыз Айтматов үз интервьюларының берсендә, Монголиядә Чыңгыз ханны милли каһарман кебек ихтирам итүләренә гаҗәпләнеп: «Монголиянең иҗтимагый үзаңы үз-үзен аңлауның һәм тәүбә итүнең әхлакый арафы аша узып үзгәрсен өчен дистәләрчә, йөзләрчә ел кирәк»,— дип әйтә. Миңа исә китапларны һәм матбугатны татар-монголлар турында ялган белән тутыруны дәвам итүче тарихчыларның тәүбәгә килүен таләп итү дөресрәк булыр кебек тоела. Монголлар ни сәбәпле тәүбә итәргә тиеш соң әле? Урта гасырларның шундый булганы өченме? Чыңгыз хан үз заманына тәңгәл ул. Чыңгыз Айтматов тагын болай ди: «Ул чакта да культураның иң түбән баскычында торган әлифбасыз халыктан чыккан Чыңгыз ханның бернинди белеме булмаган. Табигый ки, аның идеяләре бик чикле. Аныкы дип саналучы гыйбарәләр һич тә акыл һәм фикер иясенең фәлсәфи карашлары түгел, ә бәлки җәза бирүче законнар җыелмасы гына, һәм ул аяусыз изү һәм юкка чыгару юлы белән ханнар хакимиятен ныгытуга юнәлтелгән, аларда киң дәүләти фикер йөртү, бигрәк тә халык бәхете идеясен аңлау билгеләре юк». Чыңгыз хан, чыннан да, укымышсыз булган, ләкин Мөхәммәд пәйгамбәр дә белемле булмаган, алар икесе дә башкалардан өйрәнгәннәр. Чыңгыз ханда дәүләти фикерләү билгеләре юк дип әйтү дөрес түгел. Кешелек тарихында Чыңгыз хан империясеннән дә зуррак дәүләт оешмаган, мондый дәүләт төзү өчен даһиларча фикерләү зарур.

Тарихчылар үз хезмәтләрендәге каршылыкларны кайвакыт үзләре дә күрмиләр. Мәскәүнең «Вече» нәшрияты «100 диктаторов» дигән китап чыгарган, анда шундый юллар бар: «Урта Азиянең иң зур шәһәрләреннән халкы монгол гаскәрләренә батырларча каршылык күрсәткән соңгы шәһәр — Мерв. Ул 1221 елда яулап алынган. Дүрт тәүлек эчендә кешеләр үз шәһәрләрен ташлап чыгарга тиеш булганнар. Монголлар

алар арасыннан кол итү өчен 400 һөнәрчене һәм бераз балаларны аерып алганнар. Калганнар җәзалап үтерелгән, моның өчен аларны хәрби частьларга бүлеп биргәннәр: камалышта катнашучы һәрбер сугышчы үз кылычы белән 300 дән 400 гә кадәр кешене суярга тиеш булган! Ун меңнәрчә крестьян монголлар оештырган шушы зур кан коештан котылырга теләп, шәһәр читендәге тау куышларына качкан. Ибне әл-Әсир 700 мең кеше үтерелүе турында әйтә, шул ук вакытта Җүвәйни, бу санны арттырып, Изатдин Нассаба исемле ниндидер бер кешенең башка берничә кеше белән шәһәрдә үтерелгән кешеләрне саный-саный унөч көн һәм унөч төн үткәргәнлеген хәбәр итә. Тау куышларында, авылларда һәм башка буш җирләрдә үтерелгәннәрне исәпкә алмыйча, мәетләре табылган кешеләр генә дә 1,3 миллионнан артып киткән». Бу юлларны укыгач, чәчләр үрә тора, күңел татар-монголларга карата нәфрәт хисе белән тулып таша, Ибне әл-Әсир хикәятенең дәвамын укыгач, бигрәк тә: «Аннан соң монголлар шәһәргә ут төрттеләр, Синҗар солтанның төрбәсен яндырып, акча эзләп каберен актардылар. Алар бу эшне өч көн дәвам иттеләр, дүртенче көнне ул шәһәрдә яшәүче барлык кешене үтерергә боерды һәм әйтте: «Алар безгә каршы баш күтәргән иделәр». Барысын да үтерделәр. Ул мәетләрне санарга кушты һәм алар 700 мең булып чыкты. Әйе, без Аллаһныкы һәм аңа кире кайтачакбыз! Мөселманнарга менә ни булды ул көнне». Ләкин хикмәт шунда ки, урта гасырларда 700 мең кеше яши торган андый зур шәһәрләр булмаган, ул заманнарда 50 мең кеше яшәгән шәһәр дә бик зур булып саналган. Мәсәлән, XIII гасырда Бөек Новгород халкы ундүрт меңнән бераз гына артык булган. Әмма иң кызыгы шунда — бер елдан соң Мерв шәһәре яңадан баш күтәргән һәм аны, кабат һөҗүм итеп, яулап алырга туры килгән. Һәм, ниһаять, ике елдан соң шушы ук шәһәр татар-монголларга каршы 10 мең кешелек отряд оештыра, димәк, анда берәүне дә үтермәгәннәр, чөнки ун меңлек гаскәрне 40 — 50 мең (урта гасырлар шәһәре өчен мөмкин булган иң зур сан) халкы булган шәһәр генә җыя ала. 700 мең яки 1,3 миллион корбан исә «кяфер татарлар»ны күралмаган мөселман авторының фантазиясе генә булып чыга. Шул ук елъязмачы тагын болай дип тә яза: «Алар шәһәрдә үзләре күргән бар нәрсәне җимергәнче, яндырганчы, талаганчы торалар, үзләренә кирәкмәгәнне яндыралар. Ефәкне җыеп тау итеп өяләр дә ут төртәләр, шул рәвешчә алар башка әйберләрне дә юк иттеләр». Ефәкне яндыруларына караганда, моның киресенә — татарларның шәһәрне алтыннан да кыйммәтрәк булган ефәк табу өчен талауларына ышану җиңелрәк. Ефәк хакына сугышлар барган, дәүләтләр үзара берлекләр төзегән, дипломатлар һәм сәүдәгәрләр ефәкне алып кайту юлларын эзләгәннәр. Татар-монголларда ефәк уклардан саклану өчен һәм гигиена чарасы буларак кулланылган. Үз тормышларын саклаучы һәм муллык китерүче ефәкне яндырырга аларның кулы күтәрелмәс иде.

Хәзерге заман тарихчылары татар-монголларның аз санлы гаскәрләренең кытайларның, азиатларның, гарәпләрнең, иранлыларның зур армияләрен тар-мар итүгә, нык уйланылган җиңүләренә сокланалар, тик шул ук вакытта аларны варварлар дип атыйлар, башка сыймаслык саннар атап аларның коточкыч явызлыкларын тасвирлыйлар һәм күзгә ташланып торган каршылыкларны күрмиләр. Генерал М.И.Иванин Урта Азиянең, имештер, миллионлаган кешесе үтерелүен әйтә, ә соңыннан, гаҗәпләнеп, үзе үк өстәп куя: «Хива оазисында гомумән ике миллион кеше яшәве шикле, әлбәттә, ә көнчыгыш язучылары исәбенә караганда, бер Ургенчта гына да 2400 мең кеше үтерелгән!» Шуңа да карамастан ул, Чыңгыз ханның хәрби стратегиясенең һәм тактикасының, халыкара дипломатиясенең асылына төшенмичә, шушындый уйдырмаларны җентекләп тасвирлавын дәвам итә. Ул татар-монголларныкына караганда берничә тапкыр күбрәк булган хәрби көч җыеп та «варварлар» тарафыннан тар-мар ителгән Кытай империясенең, Хәрәзем солтаны Мөхәммәтнең, урыс кенәзләренең йомшаклыгына гына гаҗәпләнә. Ә «варварлар» исә ныгытылган шәһәрләрне яулап алалар, Бөек Кытай диварын серле рәвештә урап үтәләр, берничә дистә мең сугышчы аз көч белән бөтен Кытай халкын кыйный, анда ул заманда кимендә 60 — 80 миллион кеше исәпләнгән. Алар моны ничек булдыра алганнар соң? Аларның күпләп үтерү кораллары да, крематорийлары да булмаган лабаса. Шул ук вакытта кытайларның туплары һәм ракеталары «варварлар»ның атлы гаскәренә каршы ни өчендер «аз нәтиҗәле» булып чыккан. Шушындый рәхимсез сугыштан соң Кытайның атаклы киңәшчесе, фәйләсүф, шагыйрь һәм астролог Элюй Чу-цай ни сәбәпле Чыңгыз ханга хезмәткә күчкән һәм 20 ел буена канцлер булып тугры хезмәт иткән соң? Аның 1236 елгы законга ярашлы рәвештә кытай халкына, соңрак урыс халкына да салымнарны бераз йомшартуын  татар-монголлар аңлап кабул итәләр, чөнки алар мондый система икътисадны тизрәк торгызырга ярдәм итә дип санаганнар. Бу аларга ни эшкә кирәк булган? Алар бит варварлар, җимерүчеләр, бөтен кешене рәттән кыйнап-үтереп йөрүчеләр.

Чыганаклардагы саннарны китерүчеләрнең күбесе дошман ягыннан булган. Басып алучыларга карата нәфрәтләре аңлашылса да, алардан объектив фикер көтеп булмый. Басып алучыларны кем яратсын? Ләкин тарих турында язучылар елъязмачылар язганга тәнкыйди карарга тиеш бит.

Хәер, елъязмачыларның барысы да ялганчы түгел. Татар дәүләтләрендә озак яшәп телне һәм культураны белгәннәре еш кына Алтын Урдага сокланып язганнар. Гарәп тарихчыларына Бәркә ханның һәм Үзбәк ханның ислам тарафдарлары булуы йогынты ясаган, күрәсең, аларның Алтын Урдага мөнәсәбәте кискен

үзгәргән. Мисыр солтанының сәркатибе Әлмәлик-Әннәсар Ибне Фадлаллах әл-Гомәри дә, үзеннән алда килүчеләрдән аермалы буларак, Алтын Урда татарларын мактап телгә алган: «Бу илләрнең төркиләре, мин әйтәм, намуслылык, кыюлык, ялганнан качу, буй-сыннарының камиллеге, матурлыгы һәм холыкларының игелеклеге буенча Төрки кабиләләрнең иң яхшыларыннан (берсе)».

Ничек кенә гаҗәп булмасын, урыс тарихы евроцентризм эталоннары буенча язылган, гәрчә Европа тарихчылары урысларны кичәге татарлар дип исәпләсәләр дә. «Урысларның холкы, бу ярым варвар кавемнең барлык дәгъваларына карамастан, бик рәхимсез һәм әле бик озак рәхимсез булып калачак,— дип язган Астольф де Костин.— Чөнки бары тик йөз ел элек кенә алар чып-чын татарлар булганнар. Цивилизациянең әлеге сәнәктән көрәк булган вәкилләренең күпчелеге Европача көяз ялтыравык астында аю тиресен саклый — алар бары тик аның йонлы ягын эчкә каратып кына кигәннәр. Аз-маз тырнаштырып карасаң, аларның йоннары кабарып чыга һәм тырпая». Европадагы татарга каршы традиция Русиядә дәвам иттерелә, өстәвенә русофобия төсмере белән. «Көнбатышчылык» бу юнәлешнең чагылышы була да инде. Валерий Захаров язганча, «Мәскәү Русен күралмаган беренче урыс русофобы — Петр I. Урыслыктан баш тарту шушы йогышлы чирне йоктырган дворяннар арасында bon ton a (яхшы тон) билгесе булып саналган. Дворян русофобиясенә каршы күтәрелгән славянофиллар авазы урыска ачу тотучыларның шау-шуында күмелеп калган; славянофилларның ретроградлар дип даннарын сатканнар, соңрак Достоевский белән Лесковка да шундый репутация ябыштырылган». Ялган исә гадәти бер карашка, бәягә, димәк ки, үз-үзеңне тотышның стереотибын ясаучы факторга әйләнә.

Европа тарихчылары, аларга ияреп урыс тарихчылары да, сәясәтчеләр кушуы буенча, үз ялгышларын моңа катнашы булмаган кешеләргә китереп чәпәү максаты белән, кыргый татарлар турында төрле-төрле әкиятләр тараттылар. Алар моны европача, җиренә җиткереп эшләделәр. Өстәвенә төрле елъязмалардан теләсә нинди өзекләр җыярга мөмкин, чөнки төрле кешеләрнең карашлары да төрле-төрле һәм урта гасырлар вакыйгаларын шәрехләүдә аларның үз мәнфәгатьләре чагыла. Берәр нинди халыкка карата тоташ нәфрәт тәрбияләү буенча татарлар өстендә ясалган эксперименттан да рәхимсезрәген табуы кыен. Әмма бу хәл татар рухын сындыра алмады, гәрчә татарлар арасында «яхшырак», исеме «матуррак» яңгырашлы башка халык булып язылучылар да табылса да.

Русия тарихчылары үзләренең рәсми тарихларын әкият белән тутырып кына калмадылар, татарлар өчен дә татарлар килеп чыгышының «болгар теориясе»н уйлап таптылар. Әлеге теория Төрки каганлыгы һәм Алтын Урда чорларын сызып ташлый. Алар үзләренекен генә түгел, татарларның да чын тарихын юкка чыгарырга маташтылар. Татарлар арасында үз исеменнән җиңел генә баш тартучы галимнәр аз булмады. Кызганыч ки, борынгы төрки тарихын бар нечкәлекләре белән аңлаучы Садри Максуди кебек күренекле акыл ияләре дә татарларны монголларга тәңгәлләштерде, монголларны — варварлар, ә Идел буе татарларын Чулман болгарлары дип атады. Этногенез проблемаларын шулай җиңел генә хәл итеп булса икән!

Ничек кенә парадоксаль тоелмасын, әмма Садри Максуди фикеренә аның игелекле максаты — төркиләр тарихының абруен күтәрү нияте тәэсир иткән. Ул болай дип язган: «Төркиләрнең бер өлешен «татарлар» дип күзаллау һәм моннан килеп чыккан аяныч вакыйгалар татар-монгол хакимлегенең тискәре нәтиҗәләреннән берсе булып тора. Шунысын да билгеләп үтик, хәзерге вакытта «татарлар» дип аталучы халыклар тарихи яктан да, тел җәһәтеннән дә — чын төркиләр». Гомумән, язмыш җилләре Төркиягә ташлаган һәм андагы җәмгыятьтә югары урыннарга ирешкән татарлар һәрвакыт иң актив «төркичеләр» булып чыкканнар. Бик шәп сәясәтче һәм публицист Йосыф Акчура «төркичелек» теориясенә нигез салган, Садри Максуди әлеге концепциянең хокукый нигезен булдырган, Зәки Вәлиди исә, йомшак кына итеп әйткәндә, үзенең башкорт «мәгънәсезлекләренә» дә карамастан, ахыр чиктә, төрки-татар тарихы турында, ә Рәшит Арат төрек теленең реформасы хакында язганнар һәм алар барысы да бер идеягә — төркиләрнең халык буларак дәрәҗәсен күтәрү идеясенә хезмәт иткәннәр. Бу аңлаешлы хәл. Госман империясеннән Төркия республикасына күчү башка төрле тәңгәллекне таләп иткән: империячел госманлык урынына милли-төреклек соралган, димәк, төрекләрдә милли хисләрне көчәйтергә кирәк булган. Язмыш ирониясе шундый ки: аларның барысын да бүген күренекле татар (әмма болгар түгел) галимнәре һәм сәясәтчеләре буларак искә алалар.

Садри Максуди монголларны цивилизациягә ирешмәгән халык дип бәяләгән, әмма төркиләр үз тарихларын әһәмиятлерәк итү өчен башка халыкларны кимсетүгә мохтаҗ түгелләр. Варвар дип атап Чыңгыз ханның ролен кечерәйтү ихтыяҗы юк. Чынлап та, ул төрки традицияләр, төрки сугышчылар һәм киңәшчеләр аркасында күтәрелгән. Ләкин ул бит моны булдыра алган. Ул үзеннән культуралырак, оешканрак, сугыш алып баруның меңьеллык традицияләренә ия булган төркиләрне җиңгән. Чыңгыз хан төркиләр тәҗрибәсен әллә ни баетмаган, әмма күп нәрсәне, аеруча хәрби өлкәдә, камиллеккә җиткергән.

Монголларның һәм татарларның тарихын бер-берсеннән аеруы кыен. Телләренең һәм мәдәниятләрнең төрлелеге күзгә ташланып торса да, урта гасырлар тарихы аларны уртак язмыш белән бәйләгән. Кайбер та-

рихчылар, татарларның горурлыгын аярга тырышып, «монгол изүе» яисә «төрки-монгол явы» турында язалар, ләкин тарих мондый төзәтмәләргә мохтаҗ түгел. «Татар-монголлар» атамасының, ошаса да, ошамаса да, яшәргә хакы бар. Безнең язмыш уртак, аннан качып булмый. Татар һәм монгол тарихын аерым-аерым өйрәнү концепциясен аклар өчен, Казан Кремлендә күмелгән, Чыңгыз нәселеннән булган ханнарыбызның каберләрен ачып, җәсәдләрен Монголиягә илтеп куйыйкмы инде хәзер? Ахыр чиктә, бу — искиткеч тарих, аның белән горурланырга мөмкин. Вакытлар узар, бу тарихны Евразиянең күп халыклары дәгъвалый башлар әле.

## Тарих мәгънәсе

*Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,*
*Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.*
*Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,*
*Ни моңлы уйларың бар — сөйлә безгә!*
*Бабалар кабре янында күңел зар,*
*Аталар рухының армандәсе бар...*
*Кара туфрак тулы мәзлум нидасы,*
*Алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы?*

Дәрдмәнд

Бүген татарларның борынгы тарихын искә төшерергә, татар рухын тергезергә кирәк микән соң? Тормыш үзенчә бара, иске үпкәләрне яңарту нигә кирәк? Хикмәт шунда ки, тарихка кул селтәргә ярамый, бүгенге көн дә, киләчәк тә аның геннары эчендә ята. Тарих ул — бер үк вакытта аклау да, өмет тә. «Монголлар явы һәм Алтын Урда изүе урыс җирләренең Көнбатыш Европаның алга киткән илләреннән артка калуы сәбәпләреннән берсе булган,— дип язалар «Русия тарихы» дәреслегендә. Бу ялган гына түгел, бүгенге кыенлыкларны акларга тырышу да. Татарларга сылтап куясың да — бетте-китте, барысы да моңа ышаналар. Тарих хәрабәләрендә актарынырга теләүчеләр күп түгел, стереотипларга иярү җиңелрәк ләбаса.

Ә чынлыкта ничек булган соң? Чынлыкта исә кешелек тарихында чыңгызчылар империясеннән дә зуррак дәүләт булмаган, бу исә хәрби өлкәдә генә түгел, гражданнар белән идарә итү эшендә дә югары культура таләп иткән. Хәтта СССР да андый зурлыкка ирешә алмады. СССРның Көнчыгыш Европага һәм Кытайга күзәтчелек итү чоры булды булуын, ул чакта аның йогынты даирәсе чыңгызчылар империясе үлчәмнәренә якынайды, ләкин аңа җитә алмады. Чыңгызчылар шулай ук Персия, Әфганстан белән идарә иткәннәр, Багдадны яулап алганнар, Һиндстанга кергәннәр. СССР моңа омтылды, әмма куәте җитмәде.

Чыңгыз хан белән Батый хан ирешкән бик шәп һәм ашкынулы хәрби җиңүләр бүтән кабатланмаган. Урта гасырларда беркем дә аларныкы кебек камил идарә системасына, диннәргә карата тигез карашка (бусы XXI гасырда да юк), коммуникациянең гаҗәеп системасына, икътисадны һәм сәүдәне үстерә торган салым системасына ия булмаган. Хәтта татарларны дошман күргән католиклар чиркәве дә Көнчыгышка китүче миссионерларга Дон буйлап Сарай аркылы барырга киңәш иткәннәр, чөнки бу юл куркынычсызрак булган. Татар ясагы (ун өлеш, ягъни 10%) турында бүген хыялланырга гына кала. Алтын Урданың төп салымы халыктан талап алынган әйберләр түгел, ә әйләнешкә салынган салым — тамга булган, урысларның «таможня» сүзе шуннан килеп чыккан. Кефе (Феодосия), Солдайя (Судак), Тана (Азов) шәһәрләрендә Генуя кешеләренең үз кварталлары булган, Пантекапеум (Керчь), Коп (Кубань) шәһәрләрендә Венеция кешеләре төпләнгән. Бу шәһәрләр халыкара сәүдә үзәкләре булып торганнар. Ибне Баттута язуынча, Кефе — диңгезнең гаҗәеп култыгы, ул анда «200 ләп зур һәм кечкенә, хәрби һәм йөк суднолары күргән. Бу — дөнья диңгезләренең иң мәшһүр култыкларыннан берсе».

Тарихчылар ни сәбәпледер чыңгызчыларның камил финанс системасын, кешелек тарихында беренче тапкыр кәгазь акчаның Хубилай хан вакытында кертелүен искә алырга яратмыйлар. Ул акчаның үрнәкләрен — үзәгенә ал төстәге хан мөһере сугылган квадрат рәвешендәге зур кәгазь битләрен «Эрмитаж»да күрергә мөмкин. Алар Алтын Урда биләмәсендә йөргәннәр һәм бәлиш дип аталганнар. Имеш, кыргый монголларның мондый нәрсә уйлап табулары мөмкин түгел, димәк, моны акыллы кытайлар эшләгән. Өстәвенә нәкъ шул вакытта Монгол империясе башкаласын Ханбалыкка (хәзерге Пекин) күчергәннәр, димәк, чыннан да кытайлар. Татарлар үзләре булмас бит инде?!

Алтын Урда чорында нигез салынган 100 дән артык шәһәр бүген Әстерхан, Волгоград, Саратов һәм башка шәһәрләр нигезендә ята. Батый ханныкы яки Бәркә ханныкы кебек төзелешләр белән кайсы илбашы мактана ала? Андыйлар булмаган шул. Ханнар җимермәгәннәр, алар төзегәннәр. Төзегәннәр! Ибне Баттута болай дип язган: «Сарай шәһәре гаҗәеп матур һәм биниһая зур шәһәрдер, тигез җирдә утыра, халкы күп, базарлары матур, урамнары киң. Көннәрдән бер көнне аксакал белән шәһәр әйләнмәк, аның зурлыгын ча-

маламак булдык. Үзебез шәһәрнең бер башында яшәп, иртән сәфәр кылган идек, икенче башына өйләдән соң гына барып җиттек. Өйлә намазын укып, ашап алдык та кабат кузгалдык һәм үзебез торган урынга кояш батканда гына кайтып кердек». Алтын Урда шәһәрләренең башкалары турында да күргәннәр шушылай сокланып язалар. «Кыргый» халык шундый үсешкә ирешкән шәһәр культурасы булдыра алыр идеме соң?

Кылыч орсаң, колың мин җавиданә,
Вә гәр ук атсаңыз бәгъре нишанә.

Тыным барынча синдин йөз чәвермен,
Ишекнең тапракыйндин баш күтәрмен.

Камук гомрем синең назың фидасы,
Минем күңелем кошы базың фидасы.

* * *

Кил и сакый, китергел лаләгүн мәй,
Кем ул мәй кылды күпләрне Хатәмтай.

Сорахы тулса күп, агзын ачалың
Бү көн мәйханәдә ярмак сачалың.

Сабурдин яхшы юктыр, пишә кылсам,
Бу юлда сабыр юк, әндишә кылсам.

*Харәзми. «Мәхәббәтнамә». 1353*

Алтын Урда татар тарихы гына түгел, аннан башка хәзерге заман Русиясе дә булмас иде. Татарлардан башка урыслар Польшаның, Литваның, Пруссиянең, Швециянең бер өлешенә әверелерләр иде... Александр Блок үзенең «Скифы» шигырендә болай дип язган:

Для вас — века, для нас — единый час.
Мы, как послушные холопы,
Держали щит меж двух враждебных рас
Монголов и Европы!

Чынлыкта исә вакыйгалар бөтенләй башкача барган. XIII гасырдагы урыс кешеләренә немец һәм француз рыцарьларын татар-монголлардан нинди мәнфәгатьләрдә сакларга кирәк соң? Ул рыцарьлар бит Руська һөҗүм иткәннәр, Рим папасы кушуы буенча православныйларны «грек йоласы схизматиклары» дип үтергәннәр. Урысларга аларны якларга бер сәбәп тә юк. Калкан — Русь түгел. Киресенчә, Алтын Урда урысларны Европа тарафыннан йотылудан саклап калган. Нәкъ менә татарлар рыцарьларга һәм католикларга каршы калкан ролен үтәгәннәр. Әгәр дә Александр Невский Батый ханның улы Сартак белән дуслашмаса һәм татарларның атлы гаскәре аңа булышмаса, урысларга ни булыр иде дә, алар бүген кем дип аталырлар иде һәм православие кайда булыр иде икән?.. Татарлар ярдәмен санга сукмаучылар җирләрен дә, культураларын да җуйганнар.

Бик кечкенә генә «татар ясагы» өчен урыс кенәзләре үзләрен тевтончылардан саклауны таләп иткәннәр һәм татарлар аларны саклаганнар да. Хәтта Урдадагы «олы болгак» вакытында да, дәүләттә эшләр бозылып беткән чакта да, алар Көнчыгыштан бигрәк Көнбатыштан зур куркыныч янавын сизеп, ясак түләүдән туктамаганнар. Русьның Европаны татарлардан коткаруы теориясе никадәр яшәүчән булса, шулкадәр үк мәгънәсез дә. Киресен раслау дөреслеккә якынрак: күп гасырлар буе һуннар, төркиләр, татарлар көнчыгыштан кытайлылар агрессиясен тоткарлап торганнар. Алар, чыннан да, безнең эраның I гасырыннан башлап VIII гасырына кадәр кытайлар экспансиясе юлында калкан булганнар, аннан соң тәре йөртүчеләр юлына калкан куйганнар.

«Үткәнгә төбәлгән караш безне кеше яшәешенең серләренә күмә»,— дип язган Карл Ясперс. Үзеңнең чын тарихыңны белү — нәрсәгә сәләтле икәнеңне ачыклау, рухыңны коллык хәленнән чыгару һәм үзеңне бу дөньядагы вазифаңа тәңгәл рәвештә тоту дигән сүз. Тарих — язмыш ул.

Әлбәттә, бүгенгене үз кулында тоткан кеше үткәнгә дә хуҗа була, ул уйдырма тарихны көчләп тага ала, ләкин киләчәкне дә үз кулында тота дигән сүз түгел әле бу. «Сәясәт, тарих азат итмәгән очракта, тупас һәм бозык була,— дип әйткән сэр Джон Сили,— ә тарих, гамәли сәясәт белән бәйләнешне күздән ычкындырса, асылы алынып, әдәбият дәрәҗәсенә кадәр төшерелә». Тарих үз карашларында нык торырга мәҗбүр итә, вакытлы һәм узгынчы нәрсәләрдән саклый. Ул — чын һәм гадел булса — сәясәт өчен яхшы нигез, әлбәттә. Язмышны алдый алмыйсың, үткәнең генетик код сыман киләчәкне билгели. Чын тарих урынына уйдырма

язып татарларны тарихтан чыгарып ташлыйсың икән, нәтиҗәдә алдан фаразлап булмый торган билгесез киләчәккә дучар буласың, ул иртәме, соңмы синнән рәхимсез рәвештә үч ала. Русия, үткәннәр турында мифлар уйлап чыгарып, киләчәк турындагы мифлар белән яши. Ул үз-үзе була алмый.

С.М.Соловьев үзенең күп томлы «Борынгы заманнардан башлап Русия тарихы» дигән китабына кереш сүзендә болай дип яза: «Тарихчының XIII гасырның яртысыннан башлап вакыйгаларның табигый җебен (бу — кенәзләрнең нәселара мөнәсәбәтләренең дәүләт мөнәсәбәтләренә нәкъ менә акрынлап күчә баруы) өзәргә һәм татар чорын кертергә, беренче планга татарларны, татарлар мөнәсәбәтләрен чыгарырга хакы юк, нәтиҗәдә төп вакыйгалар, аларның төп сәбәпләре ябыла». Шул рәвешчә, өч гасырлык чорда урыслар язмышына гына түгел, бөтендөнья процессларына йогынты ясаган татар дәүләтләре (Алтын Урда, Казан һәм башка ханлыклар) тарихы Русия дәүләтчелеге барлыкка килү вакыйгаларының чылбырыннан төшеп кала. Ләкин «тарихи вакыйгалар үзләрен үз тирәлекләреннән тик кенә тартып алырга ирек бирмиләр» бит. Мондый ысул тупикка илтә. Шуңа да карамастан урыс тарих мәктәбе, үҗәтләнеп, шушы юлдан баруын дәвам итә. Ялгыш юл ялган нәтиҗәләргә китерә.

Икенче бер күренекле урыс тарихчысы В.О.Ключевский Русия тарихын колонизация мантыйгына ярашлы рәвештә берничә чорга бүлә. «Русия тарихы колониягә әйләнүче ил тарихы,— дип язган ул — Аның колонизация өлкәсе дәүләт территориясе белән бергә арткан». «...Илнең колониягә әйләнүе безнең тарихның төп факты булган, аның барлык башка фактлары моның белән ерак яки якын бәйләнештә торганнар». В.О.Ключевскийның тикшерү предметы, үзе язганча, дәүләт һәм халык булган: дәүләте — Русия, халкы — урыслар. Татарлар һәм аларның дәүләтчелегенә урын калмаган, гүя алар Идел буенда, Уралда, Себердә һәм Көньяк урыс далаларында яшәмәгәннәр дә. Татарларның атлы гаскәре болытлар өстеннән чабып йөргән микән әллә? Алайса, Александр Невский яки Иван Калита кенәзлек итү өчен ярлыкны кемнән алганнар соң? В.О.Ключевский үзе үк: «Ул вакыттагы Төньяк Русьның кенәзлекләре мөстәкыйль биләмәләр түгел, татарларга ясак түләүче «олыслар» булганнар; аларның кенәзләре «ирекле патша»ның холоплары дип аталганнар, Урда ханын бездә «ирекле патша» дип исемләгәннәр»,— дип яза. XIII гасырдан башлап урыслар Урда походларында катнашканнар. Ипатьев елъязмасында 1274 елда дип болай язылган: «Ул вакытта барлык кенәзләр татар ихтыярында иделәр». Әле тагын урыс тарихы өчен татар факторының әһәмияте дә булмаган, янәсе. Дмитрий Донской кем белән сугышкан икән алайса? Алдан ук ялгыш караш күренекле тарихчыларның да күзен томалый.

Лорд Актон болай дип әйткән: «Кеше язмышларының тукымасы тыгыз тукыла, анда буш күзәнәкләр калдырылмый, чөнки җәмгыять, табигать кебек, тоташ төзелмә ул...» Татарларның һәм урысларның тарихлары бер-берсеннән мөстәкыйль дип сөйләү идеологик мифлар өлкәсенә карый. «Бөек Яса», башкача әйткәндә, законнар, Алтын Урдага көч белән кертелгән яки үзләре теләп кергән бөтен урыс кенәзлекләрендә дә гамәлдә булган, акча һәм салым системасыда уртак, моның өчен халык исәбен алу үткәрелгән, кенәзләргә хакимият хан кулыннан тапшырылган, хәтта митрополитлар да, бу дәрәҗәдә расланыр өчен Константинопольгә барганчы ук, ханның ризалыгын алырга тиеш булганнар.

Русия тарихын, димәк ки, аның киләчәген дә татар факторыннан башка аңлап булмый. Русия төрки-татар империясе әверелешләренең соңгы чагылышы булып чыккан. Чумадан һәм эчке ызгыш-талашлардан үлеп баручы Алтын Урда үз төпкеленнән Мәскәү башлангычы рәвешендәге энергия куерыгы тудырган, бу куерыктан төркиләр үзләштергән шул ук территориядә яңадан империя баш калкыткан. «Русь бик бәхетле,— дип язган П.Н.Савицкий,— эчтән таркалу сәбәпле бетүгә йөз тоткан чакта ул башка берәүгә дә түгел, нәкъ менә татарларга эләккән. Татарлар — «нейтраль» культура тирәлеге, бу тирәлек «төрле аллаларны» кабул иткән һәм «теләсә нинди культуралар»га тигез караган, бу тирәлек Русь өстенә Ходай җәзасы буларак ишелеп төшкән, әмма милли иҗат чисталыгын бозмаган. Әгәр дә Русь «Иран фанатизмы һәм экзальтациясе» йоктырган төрекләргә эләккән булса, аның сынаулары да авыррак һәм язмышы да ачырак булыр иде. Әгәр дә Көнбатыш кулына төшсә, аның җаны тартып алыныр иде... Татарлар Русиянең рухи асылын үзгәртмәгәннәр; әмма ул чорда, алар өчен үзенчәлекле булган дәүләт төзүчеләр һәм хәрби оештыру көче сыйфатында, татарлар, һичшиксез, Руська йогынты ясаганнар. Үз үрнәкләрендәме, идарәчеләрнең каннарына кушылыпмы — алар Русиягә хәрби кимәлдә оешу, дәүләт — мәҗбүр итү үзеге төзү, тотрыклыкка ирешү хасияте; куәтле «урда» булу сыйфаты биргәннәр». Русия татарлардан законнар, дәүләтчелек институтлары, хәрби эшне генә алып калмаган, «татар изүе» вакытында рухын чыныктырган. Византия аның икенче чыганагы булган, әмма Византия ерак, ә татарлар — һәр көн, һәр сәгать урыслар янәшәсендә.

Русия тарихының бер яртысы гына урысныкы, икенче яртысы — төрки-татарныкы. Русия империясен төзүне башлап йөрүчеләргә Чыңгыз хан рухы күчкән, югыйсә алар мондый гаять зур максатка ирешә алмаган булырлар иде. Чыннан да, XIII һәм XIV гасырлар «Русиядә гомумтөшенкелек, тар хиссият һәм вак мәнфәгатьләр, вак җаннар чоры» булган. Кешеләр шәхси эшләр белән мәшгуль, ни фикер омтылышы, ни дәүләти идеяләр — берсе дә юк; тоташ саранлык, бу аеруча Иван Калитага (кушаматы акча янчыгы дигән-

не аңлата) һәм аның нәселенә хас булган. Мәскәү кенәзләре турында В.О.Ключевский «искиткеч тотрыклы сәләтсезлек» белән аерылып торганнар дип язган. «Бу кенәзләрдә бернинди дә яктылык, батырлык һәм әхлакый олылык билгеләре юк. Беренчедән, алар бик тыныч кешеләр, алар сугышка теләмичә генә катнашалар, катнашсалар да, күбесенчә җиңеләләр генә; алар дошманнан имән диварлар, ә Дмитрий Донскойдан башлап Мәскәү Кремленең таш диварлары артында качып утыра беләләр, дошман һөҗүм итсә, алар ашкынып Переяславльгә яки аннан да ераграк берәр җиргә — Идел буена сугышчылар җыярга китәләр, Мәскәүне сакларга исә митрополитны һәм хатыннары белән балаларын калдыралар. Алар зур талантлар белән дә, гайрәт белән дә аерылып тормыйлар, әмма бу кенәзләрдә шулай ук зур кимчелекләр яки көчле дәрт тә юк. Бу аларны күп яктан уртачалык һәм җыйнаклык үрнәкләре итеп күрсәтә, хәтта аларның төшке аш вакытында аракы белән күбрәк мавыгулары да урыс кешесенең Изге Владимир әйткән мәгълүм һәвәслек дәрәҗәсенә күтәрелмәгән. Бу — Борынгы Русьның урта кул кешеләре, тарихи шәхесләрдән бигрәк хронология билгеләре дип әйтергә була». Урысларның холкы Мәскәү хезмәтендә татарлар һәм литвалылар, соңрак немецлар барлыкка килү белән үзгәрә башлаган. Явыз Иванның атасы Василий вакытында Литвадан кенәз Глинский (сүз уңаеннан, Мамай токымы) белән бер төркем халык килгән, аларны Муром өязенә урнаштырганнар. 1535 елда, Елена Глинская идарәсе чорында, Мәскәү патшасына хезмәт итәргә хатыннары һәм балалары белән 300 «литва» гаиләсе күчеп килгән. Бу «литва»ның күбесе татар булгандыр, чөнки Мәскәү хәрби кешеләрне чакырган, ә Бөек Литва кенәзлегендә хәрби хезмәттә Мамай һәм Туктамыш урдачылары торган. Казанда әсирлектә булган Василий Темный чорында ханзадә Касыйм белән бөтен бер хәрби отряд юлга чыккан, ул Ока буендагы Городецка урнаштырылган, бирелә Мәскәү кенәзлеге составында Касыйм ханлыгы барлыкка килгән. Явыз Иван күп кенә морзаларны чакырып, аларга Мәскәү, Боров, Калуга һәм башка өязләрдә борынгыдын ук урысларныкы булган җирләрне өләшкән. 1589 елда яңа гына чукындырылган татар Кирейка Кырымнан Дон буена, казаклар янына күчеп, урыс патшасына 15 ел хезмәт иткәне, Кырым кешеләрен талавы һәм казаклар белән Кырым кешеләренә каршы сугышып йөргәне, Дон буеннан Путивльгә китеп, анда 5 ел элек өйләнгәне турында патшага сөйләгән; патшадан үзенең Путивльдәге хуҗалыгын «аклавын», салымнардан азат итүен үтенгән. В.О.Ключевский исәпләве буенча, столбовой дворяннарны теркәүче Бәрхет кенәгәдә «Бөек урыс» фамилияләре — 33%, Польша-Литвадан чыккан, ягъни күбесенчә көнбатыш урыс фамилияләре — 24%, немец, Көнбатыш Европадан чыгышлылары — 25%, татарлардан һәм, гомумән көнчыгыштан чыккан фамилияләр — 17% тәшкил итә һәм 1% ын билгеләп булмый». Польша-Литва дворянлыгының тамырлары көнбатыш урысныкы түгел, татарныкы булганын исәпкә алсак, патша хезмәтендәге татарларның өлеше күпкә зуррак булачак. П.Н.Савицкий Л.Гумилевка болай дип язган: «Мәгълүм булганча, бөек Урыс дәүләтен төзүдә зур роль уйнаган бөек урыс дворянлыгының 30, 40, хәтта аннан да күбрәк проценты бу морзаларның, кенәзләрнең, хезмәтчеләрнең нәселеннән торган». Бу хәлнең Мәскәү мөмкинлекләрен никадәр үзгәртүен аның Новгород белән бәрелешү күренешләре дәлилләп тора. 1456 елгы походта Руса янында 200 мәскәүле Новгородның татар атлы гаскәре системасында сугыша белми торган 5 мең атлы сугышчысын тар-мар иткән. 1471 елда Новгород 40 мең ополченец җыйган, әмма аларны Мәскәүнең 4 500 сугышчысы җиңгән, сугыш кырында Новгородның 12 мең сугышчысы ятып калган. Бу күренешләрдә урысларның новгородлылар кулланган традицион сугыш алып бару тактикасы белән атлы гаскәр сафында сугышуның татарлар керткән яңа тактикасы арасында аерма ачык күренә. Мәскәү гаскәрләрендә татарлар хәтта сан буенча да мөһим өлеш тәшкил иткәннәр. Маржерет мәгълүматлары буенча, XVI гасыр ахырында даими хезмәттә торган һәм жалованье алган 100 мең сугышчының 28 меңе Казан татарлары, чирмешләр һәм мордвалар булган.

Мәскәүгә Урдадан күбесенчә сәләтсез кешеләр түгел, киресенчә, маҗаралар эзләүче, хәрби хезмәттә күтәрелергә теләүче, кешеләр белән тынышмаучан, үзсүзле кешеләр киткән. «Изү», Петр Савицкий сүзләре буенча, урысның рухи үзенчәлеген коючы ут булган». Татардан килеп чыккан урыс фамилияләрен укып карасагыз, урыс тарихы да аңлаешлырак булыр. Державин — Нарбековлар, Карамзин — Кара морза, Тургенев — Тургаевлар нәселеннән, тагын Аксаковлар, Огаревлар, Чаадаевлар, Кутузовлар, Тимерязевлар һәм башкалар, һәм башкалар. Нинди мәшһүр исемнәр! Аларны санламый мөмкин түгел, аларны Русия тарихыннан чыгарып ташлап булмый, чөнки алар үзләре үк Русия тарихы.

Пушкин Борис Годунов турында Рюриковичлар токымыннан булган көнчел Шуйский исеменнән язган:

> Какая честь для нас, для всей Руси!
> Вчерашний раб, татарин, зять Малюты.

Татарның Морза Чет нәселеннән чыккан Годунов Русия патшасы булган һәм бу ул чорда табигый кабул ителгән, ә рюриковичлар — викинглар токымы, Киев Русена нигез салучылар — түбәнрәк рольләрдә булганнар. Инде Годуновны нәрсәдә булса да гаепләү мөмкин икән, бу — аның нәсел начарлыгы. Ул чыңгызчы булмаган. Тарихчылар Годуновның татардан чыкканлыгына шикләнеп бәхәс куерттылар. Мәсәлән,

Р.Г.Скрынников фикеренчә, Ипатьев монастыре монахлары язган «Чет турында хикәят»не чынлыкка туры килүче чыганак дип санап булмый. «Чет турында нәсел әкияте язганда, монахлар Борис династиясенең кенәзләрдән килеп чыгуын тарихи нигезләргә, бер очтан яңа династиянең үз монастырена борынгы бәйләнешен күрсәтергә омтылганнар. Ипатьев китапчылары раславынча, Сарайдан Мәскәүгә узып барышлый, Урда кенәзе Чет Костромада православие храмына нигез салган... Годуновның ата-бабалары татарлар да, коллар да булмаган. Кострома кешеләре борынгыдан ук Мәскәү дворына боярлар булып хезмәт иткәннәр. Бу нәселнең өлкән тармагы — Сабуровлар Явыз Иван чорына кадәр муллыкка ирешкәннәр, ә кече тармаклары — Годуновлар һәм Вельяминовлар бетүгә таба барганнар». Ихтимал, «Чет турында хикәят», бәлки, «аз гына да ышануга лаек түгелдер», әмма автор дәлилләренең нигезе юк. «Кострома кешеләре»нең урыслар да, татарлар да булуы мөмкин, өлкән тармак — Сабуровларның татардан чыккан кешеләр түгеллеген һәм башкаларны исбатлап бирергә иде алайса. Хикмәт хәтта монда да түгел. Әгәр дә инде монахлар «Чет турында хикәят»тә алдашканнар икән, ни өчен Годунов нәселен рюриковичлар яки башка урыс кенәзләре түгел, татар кенәзләре нәселе итәргә кирәк булган соң? Аңлатма бик гади — ул замандагы урыс үзаңы татарның урыс тәхетендә утыруын табигый хәл дип кабул иткән, бәлки, яратмагандыр да, ләкин түзгән. «Нәселле кешеләр патша тәхетендә табигый татарны — Морза Чет токымын күреп чирканганнар,— дип язган Николай Костомаров,— чөнки аннан да күренеклерәк нәселләр булган». Чыннан да, Годуновка каршы оппозиция булган һәм патша тәхетенә, нәселлерәк кеше дип, Симеон Бекбулатовичны утыртырга теләгән. Литва шымчылары җиткергән: «Кайбер кенәзләр һәм боярлар, аеруча аларның башында торган кенәз Бельский һәм үзенең абыйсы белән Федор Никитич, тагын күп кенә башкалар, әмма барысы да түгел, Годуновны бөек кенәз дип танырга теләмичә үзара киңәшләшә башладылар, нindидер Симеонны сайларга телиләр». Аларга Мстиславский да кушылган, чөнки ул — Симеон хатынының энесе. Явыз Иван 1574 елда Касыйм ханы Сәин-Булатны (чукындырылгач — Симеон Бекбулатович) патшалыкка куйган, аңа «бөтен Русьның патшасы — бөек кенәз» дигән титул биргән. Ул ике ел патшалык иткән, аннан соң бөек кенәз сыйфатында Тверь шәһәренә сөрелгән. Шуңа күрә боярларның кайберләре «патша» канынннан булу һәм Иван IV нең фатихасы Симеонга начар нәселле Годунов каршында зур өстенлекләр бирә дип санаганнар»,— дип нәтиҗә ясый Р.Г.Скрынников. Борис Годуновның патшалык тарихы исә татар үткәне белән араларны тиз генә өзмәгән урыс психологиясе күзлегеннән караганда бик кызыклы. Шуңа күрә танылган тарихчы Николай Костомаров сүзләрендә алдан ук ялгыш караш сизелә, ул болай дип раслаган: «Татар токымының Мәскәү тәхетендә киләчәк заманнарга төпләнеп калуы турындагы фикер Урыс җиренең тарихын, изгелеген, кадерен белгән кешеләрнең горурлыгына тигән. Әмма эш бик оста майтарылган. Борис бөтен җир тарафыннан сайланган, таҗ кидерелгән, дин йолаларын узган, патриарх һәм барлык руханилар тарафыннан хупланган патша буларак бик нык утырган. Ул тәмам законлы патша булып күренгән һәм Рюрикның яки Гедиминның бернинди токымына да халык сайлаган һәм чиркәү изгеләндергән патшаның бөек хокукларына каршы үзенең нәсел өстенлекләрен куюә көченнән килмәгән». Маржерет мәгълүматлары буенча, Борисны мәскәүлеләр яхшы идарәче буларак яратканнар. Кенәз Катырев-Ростовскийның шәхси хатирәләрендә мөлаем кеше образы килеп баса: «Бу ир кеше гаҗәеп акыллы, тәмле телле, динле, ул ярлыларны ярата, күп төзи, ул үз державасына күп ярдәм кылган һәм күп искиткеч нәрсәләр иҗат иткән». Явыз Иваннан соң Мәскәү дәүләте тынычлыкка мохтаҗ булган һәм Борис Годунов нәкъ менә шундый идарәче булып чыккан. «Элеккерәк буын Борисны безгә караганда югарырак бәяләгән,— дип язган С.Ф.Платонов.— Бу буынның Борис идарә иткән бәхетле чор, аның күңелгә ятышлы шәхесе турында хатирәләре яңа булган һәм алар шуңа таянып фикер йөрткән. Борисның замандашлары аның сөйкемлелеген аның оныкларына караганда ныграк тойганнар, әлбәттә. 1598 елгы собор аны аңлы рәвештә сайлаган һәм нәрсә сайлаганын бездән яхшырак белгән». Борис Годунов хәзергәчә билгеле булмаган яңа идеяләр әйткән: «Безнең барлык җирләребездә дә икмәк муллыгы, гаугасыз тормыш һәм барсына да тигез рәвештә иминлек, тынычлык булсын»,— дигән ул.

Борис Годуновны тәхеттән төшерүнең сәбәбе аның чыгышы буенча татар булуында да яки аңа Дмитрийны үтерүне сылтауда да түгел (моны исбатлау өчен дәлилләр аз). Сәбәп 1601—1603 елларда игеннәр уңмавында. Бу хәл бөтен Урыс җирен тетрәндергән. «Халыкның ни ашаганын Ходай үзе генә белә: үлән, печән, хәтта хайван һәм кеше мәетләре дә, моның өчен кешеләрне хәтта махсус рәвештә үтергәннәр». Икътисад бу казаны күтәрә алмаган, аннары сәяси тетрәнүләр башланган һәм Бориска карата нәфрәт туган. Борис Годунов яисә Симеон Бекбулатович шәхесләренә мөнәсәбәт нинди генә булмасын, ул аларның чыгышлары буенча татар икәнлегенә бәйле түгел.

*«Падишаһ, мәрхәмәт күрсәтеп, кешеләрне араламасын, бер-берсеннән аермасын иде, боярларга да дворяннарга һәм бояр балаларына да безгә хезмәт итүче кеше балаларына: кайберләрен кире какмасын да кайберләрен кабул итсен иде... Теләсә кемне сайлап алудан һәм*

*безгә кирәкмәгәннәрен кабул итүдән туктасын иде, һәм падишаһ аларны кире җибәрүне безгә калдырсын иде... һәм безгә килергә теләгәннәрне падишаһ, мәрхәмәтеннән аермыйча, бездән чакыртып алырга кушмасын иде; ә бездән китеп сиңа, падишаһ, үтенеч белән килгәннәрне, бездән китәргә теләгәннәрне син кабул итмәсәң иде».*

*Явыз Иванның бөек кенәз Симеон Бекбулатовичка үтенечнамәсе*
*1575, 30 октябрь*

Урыс һәм татар тарихы гына үзара тыгыз бәйләнгән дип әйтү аз булыр иде, татар факторыннан башка бөтендөнья тарихын да аңлау мөмкин түгел. Урта гасырлар картасында Европа бер бәләкәй ярымутрау гына, калганнары бар да татар җире: Кытай Тартар иле, Бәйсез Тартар иле, Дала яисә Нугай Тартар иле, Мәскәү Тартар иле, Кече яисә Кырым Тартар иле. 1348 елда билгесез испан авторы тарафыннан язылган «Libro del Conoscimento» («Гыйлем китабы») буенча Тартар иле барлык җирләрнең чиреген тәшкил иткән, чөнки аңа Азиянең яртысы кергән, ә Азия ул заманнарда бөтен җирләрнең яртысы дип саналган.

Европалы күзлегеннән караганда, бер дә юкка әрәм булып үзләштерелми яткан зур-зур җирләр татар рухының серлелеген барлыкка китергән дә инде. Татарлар иксез-чиксез һәм уңдырышсыз кебек тоелган далалардан кинәт кенә килеп чыкканнар да, башкалар җанында борчу калдырып, шулай ук тиз генә юк та булганнар, император Фридрих сүзләренчә, «җил-давылдай», ә замандашлары Маттеус Паризензис әйтмешли, «гүя Ходай каргышының ачуы ташыган яшен камчы шикелле». Алар кышын да, җәен дә пәйда булганнар. Кышкы суыктан да, комлы чүлдән дә, елга-сулардан да, урман-таулардан да куркып тормаганнар. Иң атаклы рыцарьларның армияләрен тар-мар китергән халык җылы, тыныч шәһәрләрдә гомер сөргән европалылар күңелендә өркү уяткан.

Татар җире үзеннән вакыт-вакыт, тарихчылар шәрехләвенчә,— җимергеч, ә минемчә, иҗтиһадлы энергия ташкыны чыгарган. Татар җире — татар рухы кебек үк серле, көтелмәгән һәм фараз ителмәслек бер нәрсә ул.

«Урыс рухы» яисә «урыс гаярьлеге» — инглиз, алман, француз характерына аваздаш гыйбарәләр. «Татар гаярьлеге» дип халык алдында кычкырып әйтеп карагыз менә. Бу Чыңгыз ханны терелтергә өндәү сыман яңгыраячак.

Бүгенге көндә «татар феномены»н аңлатып биргән аналитик хезмәтләр табуы бик кыен. Ул башка парадигмада булып чыга, аны аңларга яки анда иҗади башлангыч күрергә һәм бөтендөнья цивилизациясенә кертергә омтылуга караганда, кыргыйлык дип, антидөнья дип атау җиңелрәк бит. Башка халыклар хакында олы-олы хезмәтләр язылган булса да, төрки-татар культурасы турында иң тулы, иң тарихи хезмәттә дә берни таба алмыйсың. Хәтта төрки дөньяда да һуннар, Төрки каганлыклары, Дәшти Кыпчак, төрки-татар ханлыклары хакындагы белемнәр өстән-өстән генә. Безнең балалар Чингачгукның кем икәнен, индеецларның делавар яки могикан кабиләләре турында шундук сөйләп бирәчәкләр, ә менә океан аръягында түгел, элек үзенең газиз Татарстанындагы Актаныш районында яшәгән найман яисә кераит кабиләләре турында берни дә белмиләр. Татарлар темасын өйрәнгәндә, евроцентризм ише күзаллаулар аеруча комачаулый. Цивилизация һәм татарлар тарихи әдәбиятта бер казанга сыймаган тәкә башлары шикелле.

В.О.Ключевский язганча, «Көньяк урыс далалары — ерткыч күчмә халыкларның сыену урыннары». С.Ф.Платонов та «кыргый азиат күчмә халыкларын» искә ала. В.С.Соловьев күчмә халыкларны яисә татарларны, «ерткыч урдалылар» дип атап, һәрчак алар хакында «дала кыргыйлары» дип кенә яза, шул ук вакытта ул славяннарны һәм урысларны европалылар яисә «Русия рәвешле Европа» дип атый, гәрчә ул заманда Русия дә Русия булып җитешмәгән генә түгел, Европаны да һичничек мәдәни һәм психологик берәмлек дип атап булмый, ул бары географик төшенчә генә, ә менә Хәзәр һәм Болгар дәүләтләре, Дәшти Кыпчак җирләре славяннарның төньяк җирләренә яисә хәтта Киев һәм башка территорияләргә караганда да алданрак һәм яхшырак үзләштерелгән булган. Х гасыр төркиләре — болгарлары, бигрәк тә Алтын Урда дәвере татарлары Русьның төньягындагы «аю өннәре»ндә көн итүче урыслар белән чагыштырганда чын европалылар булганнар. С.М.Соловьев варварлар җәмгыятендә хөкем сөрүче «канга-кан үче» рудименты хакында үзе үк искә ала, мәсәлән, Ольганың ире өчен үч алуын тасвирлый, ул моны мәрхәмәтле гамәл дәрәҗәсенә күтәрә: «газизе өчен үч алу батырлыкка тиң», «дини бурыч, тәкъвалык бурычы». Ул заманда җинаять рәнҗетү дип саналган һәм рәнҗетелгән кемсә үзе яки аның нәселе бу рәнҗеш өчен үч алырга тиеш булган,— дип яза С.Ф.Платонов.— Кешене кенәз түгел, үз туганнары яклаган, әгәр берәүне үтерсәләр, аның өчен атасы, ир туганнары, агай-энеләре «үч алган». Үз нәсел-ыруыннан куылган кеше яклаучысыз калган, аны «эт урынына үтерергә» мөмкин саналган. Канга-кан үче җәмгыять үсешенең иң түбән баскычларына хас икәнлеге барыбызга да мәгълүм.

Яңа эра башында татарлар гына түгел, хәтта һуннар да канга-кан үче кагыйдәләре буенча түгел, ә законнарга буйсынып яшәгәннәр.

Х йөздә урысларның викинглардан аермасы аз булган, чынлыкта урыслар үзләре үк викинглар булганнар да инде. Святослав Византия императорының тынычлык турындагы тәкъдимнәренә болай дип җавап бирә: «Русь — үз кул көче белән тамак туйдыручы көнлекчеләр түгел ул». Алар күршеләрендәге халыкларны талыйлар һәм алардан җыеп алынган байлык бәрабәренә көн итәләр. Алар гадәти елга юлбасарлары булалар. Һәм инде соңрак, XII гасырда, Мстислав Новгород гаскәрен җыя һәм «Чуд җирләренә басып керә, аларны яндырып бетерә, гади халыкны әсирлеккә төшерә һәм терлек-туарны талап алып, өенә җиңүче булып, дан-шөһрәт казанып кайтып керә». «Язын ул дружинасы белән бергә яңадан уйлана башлый: тагын кая яу чабарга? Аннары үзенең кияве Полоцк кенәзе Всеславка яу чабарга була». Бу — варварларга гына хас нәрсә, аның турында С.М.Соловьев үзе үк болай дип яза: «данлы, әмма файдасыз батырлыклар белән атаклы кенәз, иске Көньяк Русьның булдыксызлыгын, киләчәк дәүләт үсешенә сәләтсезлеген күрсәткән кенәз». Төгәл генә әйткәндә, Мстислав батырлыклары белән түгел, талаулары белән данлыклы. Азиатлар ул заманда югарырак культурага һәм әхлакка ия булганнар. Әмма шулай да татарлар — һичшиксез варварлар, ә урыслар тарихларының башыннан ук цивилизацияле булганнар дигән стереотип яшәп килә.

А.Тойнби үзенең «Тарихка төшенү» дигән күренекле хезмәтендә мөмкин булган барлык цивилизацияләрне дә тасвирлый, аларны төрле сыйфатлары буенча классификацияләп чыга, әмма анда төрки-татар цивилизациясенә урын табылмаган, чөнки Көнбатыш галиме фикеренчә, татарларны цивилизация төшенчәсе белән янәшә куеп булмый, ул бөек төрки империяләргә хәтта иң борынгы (реликт) җәмгыятьләр арасында да урын бирмәгән. Ә бит бу сәхифәләрне дә тарихтан аерырга ярамый. Һәркем майя яисә ацтек кабиләләренең яки хәтта Пасха утравыннан юкка чыккан халык цивилизацияләрен белә, ә татар тарихы, татар культурасы белән бик сирәк белгечләр генә шөгыльләнә. Арнольд Тойнби язганча: «Көнбатыш диңгезчеләре ачканчы Пасха утравы күршеләреннән аерым яши һәм алар белән бәйләнештә булмый. Әмма андагы «таш балбаллар» җир йөзеннән юкка чыккан цивилизация булганлыкны аңлата, күрәсең». Пасха утравы турындагы барлык фикерләр күзаллауларга корылган, әмма бу фикерләр ачык һәм төгәл булган очракта да әллә кайда Тын океандагы бу утрауның бөтендөнья тарихына йогынтысы юк — кешеләр шушы утрауда үз көннәрен үзләре күргәннәр, ә йөзләгән еллар дәвамында Евразия тарихын барлыкка китерүче Чыңгыз ханга һәм татарларга тарихи хезмәтләрдә урын җитми калган. Моны ничек аңлатырга соң? Европа тарихчылары өчен татарлар — антидөнья. Алар дала, күчмә халыклар факторына, монгол татарлары факторына, исемнәрен атамыйча гына, вакыйгаларга һәм халыкларга әйләнә-тирә басымы буларак кына мөрәҗәгать итәләр. А.Тойнби болай дип яза: «Казаклар урыс православиесенең Евразия күчмә халыкларына каршы торучы чик сакчылары булдылар». Һәм аннары, казакларны тәре йөртүчеләрнең рыцарь ордены белән чагыштырып, даладагыларга каршы торучы культура, цивилизация буларак чагылдыра. Моннан да уңышсызрак чагыштыруны уйлап табарга да мөмкин түгел. «Казак» төрки телдә элек-электән «ирекле кеше» дигәнне аңлата, ул ханнар хакимиятенә буйсынмый, бер катламга да керми, гадәттә, берәрсен талар өчен далага китә. Нинди рыцарь булсын инде ул! Соңыннан гына алар хан яки атаман сайлап куялар һәм оешкан көчкә әверелә. Ә Идел һәм Дон елгасы буйларында йөргән казакларга килгәндә исә, гәрчә А.Тойнби аларга сокланып язса да, алар — ушкуйниклар, ягъни елга юлбасарлары булганнар. Казакларда иҗтимагый тормыш үсеш алгач, алар Русиягә килеп кушылганнар. «Дала» белән «көрәш»тә аларның бертөрле дә тарихи роле булмаган, ә аларның нииндидер күчмә халыкларны мифик җиңүләрен күчмә халыклар дөньясының таркаулыгы белән аңлатып була. Әмма бу сюжет тарихчыларның евроцентристик менталитеты күзлегеннән карaганда гаять кызыклы. Алар фикеренчә, «татарлар» һәм цивилизация, «татарлар» һәм культура төшенчәләрен янәшә куярга ярамый. Татарлар тарихы — капма-каршы дөнья ул, анда халыкларның үз исеме юк, аларны күчмәләр, варварлар, кыргыйлар дип кенә атыйлар. Бу антидөньяны аңлатып та, аңлап та, кабул итеп тә булмый. Ул тышкы тирәлек кебек, ягъни А.Тойнби сүзләренчә, ул «басым ясау стимулы», кояштагы таплар сыман, без аларны күрмибез, әмма алар китергән зыянны тоябыз.

Урыс язучыларының һәм философларының рәсми тарих язмалары белән күзләре шулкадәр томаланган була, алар хәтта аермачык нәрсәләрне белергә дә, күрергә дә теләмиләр. Алар Александр Македонский, Юлий Цезарь, Наполеон, Бисмарк максатлары турында фикер йөртәләр, Борынгы Мисыр, Борынгы Кытай турында сөйлиләр, әмма Чыңгыз ханны белергә дә теләмиләр, ә аның каны, өлешчә генә булса да, аларның үзләрендә дә бар лабаса. Бу — антидөнья, ул күзгә күренми, аның яшәргә хокукы юк. Ходай язмасын! Наполеонга сокланып, ул кылган гамәлләрнең һәм урысларның аны җиңүенең әһәмиятен аңлап, шулар хакында сөйләү яхшырак бит. Ә татарлар исә булмаган. Вәссәлам!

Чын тарих башканы күрсәтә. Төркиләр Бөек Даланың гаять зур территорияләрен дә, елга үзәннәрен дә үзләштерүгә байтак өлеш керткәннәр. Алар хәрби сәнгатьне генә түгел, терлекчелек, игенчелек, шәһәр төзелеше культурасын да үстергәннәр. Цивилизацияне коммуникация чараларыннан башка күз алдына да ки-

тереп булмый, коммуникация чаралары исә урта гасырларда төркиләрдә югары үсеш алган. Төрки-татар дәүләт структуралары урта гасырлар өчен үрнәк була, хәзерге Русияне дә, бүгенге Төркияне дә һәм башка илләрне дә алардан гайре күз алдына китерүе кыен. Дөнья йөзендә шулкадәр империяләр һәм милли дәүләтләр төзегән халыклар бик аз.

И вечный бой! Покой нам только снится
Сквозь кровь и пыль…
Летит, летит степная кобылица
И мнет ковыль…

И нет конца! Мелькают версты, кручи…
Останови!
Идут, идут испуганные тучи,
Закат в крови!

Закат в крови! Из сердца кровь струится!
Плачь, сердце, плачь…
Покоя нет! Степная кобылица
Несется вскачь!

*А.Блок. «На поле Куликовом»*
*1908, 7 июнь*

Ни өчен соң бөек төрки-татар цивилизациясе тарих күләгәсендә калган? Ни өчен соң кайбер илләр алга китә дә, икенчеләре юкка чыга? Моны техника прогрессына, географик урынга, бүтән факторларга сылтап була. Әмма тарихның юнәлешен билгеләүче тагын бер критерий бар бит. Иммануил Кант раславынча: «Дөнья тарихы — ул бары тик Ирекне аңлау прогрессы». Тарихның иң ахыргы мәгънәсе азатлыкны арттыру. Кеше ирекен арттырган цивилизацияләр генә яшәп калганнар һәм алга киткәннәр. Башкаларның язмышы реликт цивилизацияләрнең язмышын кабатлый. Ирек ул, ахыр чиктә, икътисади һәм техник үсешне аңлата. Тиран һәм деспот режимнар да билгеле бер чорга хәрби яисә икътисади өстенлекләргә ирешкәннәр, әмма озак дәверләр масштабында караганда, сәяси ирек рух үсешен билгели, ә ирекле рух фән, техника ачышларына китерә, илләрнең һәм халыкларның үзара ярышына этәргеч була. Үзгәртеп коручан рух белем һәм ихтыяр таләп итә. Бу гомер бакый шулай булган. «Ирек һәртөрле алга китешнең бердәнбер хаклы һәм үзгәрмәс чыганагы ул,— дип яза Джон Стюарт Милль,— ирек булган җирдә күпме индивидуум булса, алга китешнең бер-беренә бәйсез үзәкләре дә шулкадәр үк булырга мөмкин. Хәер, прогрессив принцип нинди генә чагылыш тапса да — ирек яратумы яки алга китешне яратумы — һәр очракта гореф-гадәтләрнең өстенлегенә каршы тора һәм ул кешеләрне шушы изүдән коткарырга омтылуны күздә тота. Кешелек тарихының бөтен галәмәте дә шушы принцип белән гореф-гадәт арасындагы көрәштән гыйбарәт. Дөресен генә әйткәндә, дөньяның күп кенә өлеше гореф-гадәт чиктән тыш хакимлек иткәнгә күрә тарихсыз калган».

Татар дәүләтләренең дә язмышы сәяси һәм икътисади ирек кысалары белән билгеләнә. Алар төрле һөнәрләргә, фәннәргә, рухи ирек үсешенә этәргеч биргән заманнарда җәмгыять алга киткән, хәрби сәнгать — тиңдәшсез, дәүләт идарәсе — нәтиҗәле, финанслар системасы камил булган. Биләмәләрне арттырган вакытта иске формаларны үзгәрешсез калдыру зыянга эшли башлаган. Җәмгыять зурая һәм катлаулана барган саен, аның сәяси оешуының нәтиҗәлелегә мөһимрәк була бара. Алтын Урда урта гасырлар азагында үзенә ярашлы сәяси формалар таба алмаган. Ул корылтай һәм дүрт бәк системасы рәвешендә сайлау системасына якынайган, әмма дан-шөһрәткә омтылучы дала юлбашчыларын сәяси системага кертеп җибәрерлек адым ясарга өлгерми калган. Азатлыкка омтылу хисе татарларда бик үзенчәлекле чагылыш тапкан: казаклар — ирекле кешеләр барлыкка килгән. Әмма аларның далага — үз-үзен югалта баручы цивилизациягә китүләре тарихи драмага әверелгән, гәрчә даланың күчмәлек демократиясе үзенә тартып торса да.

Алтын Урданың зәгыйфьләнә баруы цивилизацияләрнең котылгысыз бәрелешеннән килеп чыга. Техник яктан Европадан яки Русьтан сизелерлек артта калу да күзәтелми, Урда гаскәрләре өр-яңа идеяләрне үзләштергәннәр һәм үзләренең атлы гаскәр тактикасына кертә белгәннәр. Мәсәлән, алар, бәләкәй тупларны иярнең ике ягына бәйләп, атта барганда ук дошманга ядрә яудырганнар. Урыс елъязмаларында Болгар тирәсендәге яу турында искә алуларда «кайберләре безнең гаскәрләрне өркетеп, шәһәрдән күк күкрәттеләр» диелә, ягъни туплардан атканнар. Цивилизацияләр арасындагы әчке конфликттан җәмгыятьнең көче кими барган. Европа инде авыл хуҗалыгы белән ныклап шөгыльләнгән, кайбер илләр сәнәгатьне үстерүгә дә ирешкән, ә татарлар исә берьюлы ике цивилизация вәкилләре булганнар: күчмә тормыш һәм дә игенчелек. Урданың үз эчендәге бу көрәштән яңа тәртипләр яклы урдалыларны үз якларына аударган урыслар җиңүче булып чыккан. Шулай итеп, Алтын Урданың үзендәге ике цивилизация конкуренциясе әкренләп Урданың

аерым өлешләрен үз эченә алган, яңартылган Русь конкуренциясенә әверелгән. Әгәр дә Аксак Тимер Идел буе шәһәрләрен яндырып чыкмаса, Сарай, Болгар яисә Үкәк (хәзерге Саратов) башлап йөрүчеләр булыр иде. Урыс шәһәрләрен Аксак Тимернең җимергеч явыннан урманнар саклап, коткарып калган.

Алтын Урда күчмәләр культурасының азагын — кояш баешын аеруча төгәл чагылдыра һәм анда цивилизацияләр конфликты фаҗигале төсмер ала — тарих шушы культура рәвешендә үзенең гаять мәгърур сәхифәләре белән хушлаша. Алтын Урдадан соң булган ханлыклар сәяси һәм иҗтимагый тормышка яңа элементлар кертә алмыйлар, алар, элеккеге гореф-гадәтләрне ныгытып, иске тәҗрибәне генә кабатлыйлар, менә шул аларның язмышын хәл итә дә инде.

Умчались, пропали без вести
Степных кобылиц табуны,
Развязаны дикие страсти
Под игом ущербной луны.

И я с вековою тоскою,
Как волк под ущербной луной,
Не знаю, что делать с собою,
Куда мне лететь за тобой!

Я слушаю рокоты сечи
И трубные крики татар,
Я вижу над Русью далече
Широкий и тихий пожар.

*А.Блок. «На поле Куликовом»*
*1908, 31 июль*

Игенчелек строе һәм православиенең үтеп керүчән роле урыс кенәзлекләрен күтәрү факторлары булган, әмма Мәскәү сәяси ирекләрне арттыруга омтылыш ясамаган, ул хәтта сәяси культурага башбаштаклык керткән, бу урыс дәүләтен баштан ук кимчелекле иткән. Опричнина исә урыс дәүләтенең бөтен дәверендә иң начар уйлап табуларның берсе булган. Ермак Себерне буйсындыручы буларак мәгълүм, әмма ул тормышын ушкуйник буларак башлап җибәргән. Аннан аермалы буларак, Чыңгыз хан нойоннары «Бөек Яса» кануннарына буйсынганнар. Явыз Иван, Петр I кебек үк, законлы кагыйдәләргә караганда үз капризларын ешрак үтәгән. Без — шул заманнардан калган җимешләрнең ачысын татучылар. Ни өчен болай килеп чыкканына мең төрле сылтау табып була, әмма кеше иреген Явыз Иван, Петр I, Сталин кебек чикләүләрне берничек тә аклап булмый, чөнки тарихның төп мәгънәсе — кешенең ирeген арттыруда. «Кешелекнең бөтен тарихы индивидуальләшүнең өзлексез процессыннан һәм шуның белән бергә ирек факторының әһәмиятен арттырудан гыйбарәт,— дип яза Эрих Фромм.— Ирекка омтылыш метафизик көч түгел, аны табигать законнары белән дә аңлату мөмкин түгел; индивидуальләшүнең һәм мәдәни аң үсешенең кире кайтарылмас процессларының котылгысыз нәтиҗәсеннән гыйбарәт ул. Авторитар көчләр ирекка омтылуны китереп чыгаручы төп факторларны юкка чыгара алмыйлар; шулай ук шушы шартларның нәтиҗәсе булган ирекка омтылуны да юкка чыгарырга хәлләреннән килми аларның».

Тарих ул — башбаштаклыкны чикләү аша ирекләрне арттыру. Менә нәкъ шул халык рухын үстерергә ярдәм итә дә инде, ә халык рухы исә ирекле фикер йөртү бәрабәренә яңа идеяләр таба. Гадәти хокуклар урынына — законнар, канга-кан үче урынына — суд, парламент белән чикләнгән корольләр хакимияте, монархияне алмаштыручы демократия, механик күпчелек диктатурасы урынына алга киткән демократия — бөтендөнья тарихында башбаштаклыкны җиңү баскычлары шулар. Башбаштаклыкны чикләү халыкның рухын тарихи иҗат өчен азат итә. Нинди генә сәбәпләргә нигезләнмәсен — авторитаризм, деспотлык, тиранлык, ирек чикләүнең теләсә нинди рәвеше тарихи аклаудан мәхрүм. Кирәклеккә сылтап каты куллы хакимият урнаштыруны да аңлатып була, җәмгыятьнең башкача чарасы юк иде дип тә «дәлилләп» була, әмма бу очракта илнең һәм җәмгыятьнең «запас юлда» калуын көт тә тор һәм, шушы тупиктан чыгып, алга киткән халыкларны куып тоту аеруча кыен булачак.

Иректән башка идеяләр, оригиналь хәл итүләр конкуренциясе мөмкин түгел, ә яңа идеяләрдән башка җәмгыять таркала башлый. Җәмгыятьнең күптөрлелек палитрасы гореф-гадәтләр, конформизм басымы астында калып, кимсетелгән, чикләнгән, мескен кешеләр үстерәчәк, гарип җаннар тудырачак. Вильгельм Гумбольт фикеренчә, кешелек үсеше өчен ике шарт зарур: ирек һәм күптөрлелек. Шуңа күрә дә Европа, борынгы цивилизацияләрдән узып китеп, йөзләгән еллар буена алга бара, чөнки ул ирекләрне бертуктаусыз арттыра һәм мәдәниятләр төрлелеген саклап килә. Индивидуумнар, сыйныфлар һәм халыклар конкуренциясе өзлексез, даими прогрессны тәэмин итә.

Гадәттә кешеләр үз фикерләрен башкаларга тагарга омтыла, ә кулында хакимият тә булса — ул аларны бөтен җәмгыятькә тагарга тырыша, шул ук вакытта алар җәмгыять үсешенең ниндидер идеаль моделе булуга ышаналар һәм нәкъ менә үзләрен шул модель ияләре дип атыйлар. Тарихның ниндидер ахыр максаты бар дип исәпләү — хата фикер. «Шулай ук барлык бәндәләргә дә, кая гына булсалар да, котылу алып килерлек бердәнбер хакыйкать доктринасы, табигый хокуктан яисә изге китаптагы вәхиләрдән йә даһи кешенең күрәзәләреннән, йә гади кешеләрнең табигый акылыннан, йә кешелек дөньясына идарә итәргә куелган галим-утилитаристлар элитасының исәпләп чыгаруларыннан торган доктрина турындагы төшенчә дә шулай ук хата фикер». Беркем дә иң олы хакыйкатьне белә алмый һәм берәүнең дә үз доктринасын җәмгыятьнең бердәнбер моделе буларак башкаларга көчләп тагарга хакы юк. Дж.С.Милль исәпләвенчә, «башкалар уйлавынча, теге яисә бу гамәлне башкару дөресрәк яки мактаулырак булуга карап, беркемнең дә индивидуумны теге яки бу гамәлне кылырга яки кылмаска мәҗбүр итәргә хакы юк». Карлейль бу хакта болайрак фикер йөртә: «Адәм актыкларын теләсә нинди юллар белән рәтлерәк итү, дуңгызларны яхшырак итү гөнаһ, имеш...». Бу ике караштa да чын либерализм белән, Николай Бухарин сүзе белән әйткәндә, кешеләрне бары тик «кеше материалы» гына дип санаганнарның бөтен кешелеккә үз фикерләрен тагучы доктриналары арасындагы аерма чагыла да инде. Көчләп тагылган бәхет бәхет түгел инде ул. «Беркем дә мине үзе аңлаганча бәхетле итә алмый,— ди Иммануил Кант.— Патернализм — күз алдына китерергә мөмкин булган иң олы деспотчылык ул». Кешеләрдән алар үзләре ирешә алмаганны әвәләү, үзләренә ни кирәген һәм үзләре өчен нәрсә яхшы икәнлеген дә аңламаган кешеләр көтүеннән рөхсәт яисә ризалык сорап тормау — диктаторның мантыйгы менә шундый. Ул кешеләрнең күбесе традицияләргә таянып яши дип раслый, шуңа күрә дә үз режимын «бик кирәкле» дип аталучы ниятләре белән аклый, әмма шул ук вакытта кешеләргә, тышкы, ялтыравык холык-тәртип үрнәкләрен көчләп тагып, аларны үсеш мөмкинлекләреннән мәхрүм итә ала.

Огюст Конт сорый торган булган: «Әгәр без химиядә яисә биологиядә фикер ирекен рөхсәт итмибез икән, ни өчен без аны әхлак яисә сәясәттә рөхсәт итәргә тиеш?» Мондый мантыйк беренче карашка гына ышандыра. Чынлыкта исә иҗтимагый тормыш табигатьтән тамырдан аерылып тора. Анда кырыс детерминизм юк. Тарих субъекты, табигать, ландшафт, климат теге яки бу хайванның (мәсәлән, дөя яисә атның) яшәеше этник, физиологик һәм башка факторларны билгеләгән дәрәҗәдә үк тарихи законнарны билгели. Әхлакый нормалар, аларны сайлап алу һәм аларның нәтиҗәлелеге бәхәссез һәм объектив факторлар. Иммануил Кант исәпләвенчә, тышкы дөнья белән идарә итүче законнар барлык нәрсәләргә дә идарә итсә, әхлакның җир йөзендә эзе дә калмас иде. Иҗтимагый тормыш очраклы хәлләр белән билгеләнмәгәнгә күрә, әхлакый җаваплылык яшәп килә, димәк, сайлау ирекe дә, гамәл ирекe дә бар. Мондый очракта сайлау ирекe мөмкинлеге тарихи үсешне билгеләүче төшенчәләрнең берсенә әверелә. Кеше белән табигатьнең һәм башка кешеләрнең үзара йогынтысында яңа бер нәрсә барлыкка килә һәм мондый яңалык — кешеләргә аеручa хас үзенчәлек. Тормыш бит ул — төгәлләнмәгән, даими рәвештә үзгәреп торучан, көтелмәгән бер нәрсә. Кешеләрне яхшылыкны яманлыктан аера белү сәләте кеше итә, шуңа да ирек бәһасез була. Кеше әйләнәтирә табигатьтән өстенлек итүе белән генә, фикерләвенең рациональлеге белән генә түгел, сайлау һәм эксперимент ирекe белән дә аерылып тора. Төгәл детерминизм юк икән, иҗтимагый корылышның идеаль моделе төшенчәсе дә үз асылын югалта, диктатураны аклау да үзеннән-үзе юкка чыга. Хакыйкать ирекле һәм азат бит.

Либераллар мәгърифәтнең иксез-чиксез көченә һәм әхлакның бөтен кешеләрне бай һәм тигез итә алуына ышанганнар. Социалистлар икътисади ресурсларны контрольдә тотуга һәм бүлешүгә ышанганнар. Идеяләр ярышында беренчеләре җиңеп чыккан. Социализм да, авторитаризмның башка рәвешләре дә һәрьяклап җиңелүгә дучар булды. Джон Стюарт Милльнең «Ирек турында» дигән кечкенә генә брошюрасында — сэр Ричард Ливингстон сүзләренчә «бөек юка китапчыкта» кеше ирекe турындагы идеяләрнең иң яхшысы бәян ителгән. Либерализм турында шуннан соңгы барлык хезмәтләр теге яки бу рәвешле Дж.С.Милль фикерләре тирәсендә бөтерелә. Шул ук 1859 елда Карл Маркcның «Сәяси икътисадны тәнкыйтьләү» китабы дөнья күрә, анда тарихны материалистик аңлау нигезләре бәян ителә. XX гасыр буеннан-буена либераль идеяләрнең либерализм белән көрәшенә әверелә һәм социалистик дөньяны тарихи мәгънәсезлеккә китерә.

Бүген иң йогынтылы концепцияләрнең барысы да, аермалары күплегенә карамастан, либерализм идеяләренә таяналар. Либерализм заманнары тәмамланды дип белдерүче сәясәтчеләр дә бар, билгеле. Иммануэль Валлерстайн: «Бүген либерализм үз мантыйгыннан үзе аптыраштa. Ул кеше хокукларының законлылыгын һәм аз-азлап кына булса да халыкларның хокуклары законлылыгын раславын дәвам итә. Ул хокукларның тулы күләмдә үтәлмәячәген белсә дә, һаман шуларны раслый. Бу торган саен кыенлаша. Ә, кем әйтмешли, Сцилла белән Харибда арасына кысылган либераллар, күпчелеге — консерваторларга, бик азы гына радикалларга әверелеп чын йөзен ача бара». Либералларны болай бәяләү идеологиянең үзен инкяр итү түгел, билгеле, монда хәзерге дөньядагы сәяси, хәтта партиячел юнәлеш буенча тәнкыйть ясала. Либе-

рализм идея агымы буларак үзенең әһәмиятен саклап кала һәм әлегә кадәр кешелек дөньясы шуннан да йогынтылырак, шуннан да универсальрәк нәрсә уйлап тапканы юк әле.

Либерализм иҗтимагый тормышның минималь таләпләренә каршы килмәгән хәлдә, мөмкин кадәр тыкшынмауны таләп итә. Әмма шәхси ирек башкалар иреген дә чикләмәскә тиеш бит. Ирек ул без үзебез урнаштырган законга буйсынуны күз алдында тота. Локк әйтүенчә, «Закон булмаган җирдә ирек тә юк», чөнки әйбәт законнар, гадәттә, җәмгыять файдасына эшли.

Ирек тотрыклылык, бердәмлек, туганлык кебек бүтән кыйммәтләрне гамәлгә ашыруга да каршы килергә мөмкин. Ярлы-ябагайга ирек турында гәп сату көлке, анда корсак кайгысы, аның өчен итек-кәвеш Шекспирдан мөһимрәк, әмма сәяси ирекләре булмаган җәмгыятьнең, нефть ятмалары булмаса, баю мөмкинлеге юк. Томас Гоббс фикеренчә, кешеләр өчен иң кыйммәте, иң кирәклесе — куркынычсызлык, имин тормыш. Кешелек дөньясының күпчелеге рәхәт тормыш, иминлек, дан-дәрәҗә, хакимият, киләчәк тормышта бүләкләүләр хакына ирегеннән корбан итәргә әзер, әмма бу җәмгыятьнең кеше ирегеен арттыру ягына таба юнәлешен үзгәртми.

Иҗтимагый система гадел һәм әхлакый җәмгыять төзү өчен алшарт ролен үтәүче ирек урнаштыру белән генә шөгыльләнми. Әгәр бер халыкның яки бер социаль катламның ирегe икенче бер халыкның яисә сыйныфның хәерчелегенә бәйле икән, мондый җәмгыять гаделсез һәм әхлаксыз җәмгыять була. Чынлыкта исә, Исайя Берлин язганча, «хокукый ирекләр кешеләрне рәхимсез эксплуатацияләү, кансызлык һәм гаделсезлек белән янәшә хөкем сөрә алмый». Ирекле базар асылда кешенең төп хокукларын тупас бозуларга, гаделсезлеккә китерә, бирәүләрне икенче берәүләр тарафыннан эксплуатацияләүгә этәрә, җәмгыятьне байларга һәм ярлыларга бүлгәли. Ирекле базар да, сайлаулар процедурасы буларак, демократия дә ирек белән гаделлеккә тәңгәл түгел.

Механик күпчелек ихтыяры булган очракта, демократия дә, диктатура кебек үк, гаделсезлеккә китерергә мөмкин. Демос, ягъни Борынгы Афина халкы закон чыгару, суд һәм хәтта башкарма хакимиятне дә үз кулына алган. Ул чактагы философия афиналыларны, дәүләт законыннан да өстен закон юк һәм закон чыгаручы законның үзеннән дә өстен, дип өйрәткән. Демосны тотып торырлык көч булмаган икән, димәк, тотып торырлык бурычлар да булмаган, закон чыгаручылар, үзләре урнаштырган законнардан гайре, бернинди законнарга да бәйле булмаганнар һәм Афина халкы тиранга әверелә барган, ә аның демократик дәүләте борынгы греклардан чыккан акыл ияләре каргышына тап булган. Афиналылар Сократны бәйсез фикер йөрткән өчен үтергәннәр. Бу стройны Аристотель охлократия, ягъни котырган гавам хакимияте дип атаган. Чирек гасырдан соң афиналылар кеше ирегеен, гаделлекне һәм закон алдындагы тигезлекне гамәлгә ашыру өчен демократия шул ук дәрәҗәдә үк үзен дә чикләргә тиеш, ә үткән заманда олигархия дә үзен шулай ук чикләргә тиеш булганлыгын аңлыйлар. «Азчылык изүендә яшәү коточкыч,— дип яза лорд Актон,— әмма күпчелек изүендә яшәү тагын да куркынычрак. Массалар ниндидер яшерен энергетик куәткә ия һәм ул тышка бәреп чыкса, азчылык аңа бик сирәк очракта гына каршы тора алачак. Бөтен бер халыкның үзхакимлеге ихтыярына нәрсә каршы торырга мөмкин соң? Монда үтенү-ялвару да, шикаять-кызгандыру да, хатагөнаһларыңны тану да ярдәм итми, бердәнбер юл — хыянәт кенә кала». Лорд Актон бу сүзләрне әйткәндә фашизмның коточкыч галәмәтләрен күз алдына китерү дә кыен булган әле. Гитлер хакимияткә демократик юл белән килгән, аны сайлап куйганнар. Механик күпчелек демократиясенә таянучы, иҗтимагый катламнарның һәм мәдәниятләрнең күптөрлелеген искә алмаган иҗтимагый строй хакимиятне үз кулына туплаган бер кеше диктатурасы кебек үк куркыныч тиранлыкка әверелә. Мэдисонга атаган хатларының берсендә Джефферсон болай дип яза: «Хәзер дә һәм тагын күп еллар дәвамында да иң зур афәт закон чыгаручылар тиранлыгы булачак әле». Җәмгыятьтә беркем дә җимерә алмаслык ирек чикләре хөкем сөрергә тиеш. Һәр кешенең, һәр халыкның, һәр дәүләтнең үз суверенлыгы чикләре булырга тиеш. «Абсолют суверенлык доктринасы — үзеннән-үзе тиранлык ул». Ирек кешеләр белән идарә итүче затның яисә органның (алар нинди генә идеалларга таянса да) хакимиятен чикләүгә бәйле. Әгәр мине игелекле максатлар өчен дип мәҗбүрилиләр икән, димәк, минем ирегем кысыла дигән сүз.

Русия өчен тарихи сабак дигән нәрсә юк бит. Ул бүген дә кеше ирегеен чикләүче доктрина әзерләп маташа. Дәүләт Думасы 2004 елгы сайлаулардан соң механик күпчелек тиранлыгына әверелде, закон чыгаручылар Конституциядән, җәмгыятьтән дә өстен була башладылар, алар үз суверенлыкларының җәмгыять алдындагы җаваплылыклары белән чикләнгәнлеген оныттылар. Бернәрсә белән дә чикләнмәгән суверенлык — җәмгыять өчен куркыныч нәрсә ул. Суверенлык хакимият тармаклары, территорияләр һәм шушы илдә яшәүче халыклар арасында бүленергә тиеш. Шул очракта гына демократия кеше ирегеен тәэмин итәчәк. «Дәүләтнең ирeклелеген раслаучы иң ышанычлы күрсәткеч — азчылыкның иминлек дәрәҗәсе». Демократия һәм тигезлек хакына, Алексис де Токвиль сүзләренчә, күп кенә кешеләр еш кына «күндәм сарыкларга» әвереләләр, алар арасындагы «уртакул кешеләр күмәклеге» аерым кешеләрнең үзләренә генә хас сыйфатларын һәм индивидуаль талантларны юк итә. Механик күпчелек демократиясенә каршы дәва мо-

нархиядә дә, социализмда да түгел, ә демократиянең үзенең либерализмга таба күбрәк авышуында. «Ирек ул — югарырак сәяси максатка ирешү чарасы түгел. Ул үзе — иң югары сәяси максат».

## Этноним язмышы

*Аларның гадәттән тыш бөеклеге һәм мәртәбәле, ихтирамга лаеклы булулары аркасында, башка төрки кабиләләр, дәрәҗәләре һәм исемнәре төрле булса да, алар исеме белән мәгълүм булдылар, шул исем астына берләштеләр һәм татарлар дип атала башладылар. Аларның төрле ырулары үз бөеклеге, үз абруе үзләрен алар дип санауларында икәнлекне аңладылар һәм алар шул исем белән билгеле булдылар, хәзерге вакытта Чыңгыз хан һәм аның нәсел-ыруы идарә иткәнгә күрә (чөнки аларның асылы монголлар) җалаирлар, татарлар, айратлар, онутлар, кераитлар, найманнар, тангутлар ише күп кенә төрки кабиләләр, һәрберсенең үз исеме һәм махсус кушаматы булса да — алар барысы да, электә бу исемне танымасалар да, мактанышып, үзләрен монголлар дип атыйлар бит — шуның кебек.*

Рәшидетдин.«Җәмигъ-әт-тәварих»
1330 —1311

Теләсә нинди этноним метаморфозалар, ягъни үзгәрешләр, әверелешләр кичерә, вакыт-вакыт алар шулкадәр катлаулы була ки, башлангыч тамырларын эзләп табу да кыенлаша. Йә, кем әйтеп бирә ала: «урыс» (русские) дигән этноним каян килеп чыккан? Варягларданмы, әллә славяннарданмы? Һәм ни өчен халык исеме сыйфат белән белдерелә, башка халыкларда бит «татарныкы» яки «французныкы» димиләр, алар — татарлар, алар — французлар...

«Татар» этнонимының язмышы шактый катлаулы. Башлап бу атаманы Бөек Кытай диварыннан төньяктарак яшәгән халыклар йөрткәннәр. Аларның көч-куәтенә карап, кытайлар Кытайдан төньяктарак яшәгән барлык халыкларны «татар» дип атый башлаганнар, ә территориянең үзе «Дәшти Татар» — «Татар җире» дип исемләнгән. Кытай тарихчылары исәпләвенчә, «татар» термины җыелма мәгънәгә ия. Э.Х.Паркер «Татарлар тарихыннан мең ел» дигән хезмәтендә, Кытай хроникаларына таянып, гуннарны (һуннарны), аварларны, төркиләрне, сяньбийларны татарлар дип атый. Ул заманнарда без уйлаган мәгънәдә этниклык та, милләт тә булмаган. Кабилә-ырулар җиңел генә килеп кушылганнар да җиңел генә аерылып та киткәннәр, кабиләләр үзара берлекләр оештырганнар, ә нәсел-нәсәбәләрнең яисә юлбашчыларының исемнәре этносларның атамасына әверелгән. Шул ук вакытта тел һәм мәдәният элеккегечә кала алган.

Кайбер белгечләр фикеренчә, иң борынгы татарлар монгол телендә сөйләшкәннәр, әмма Рәшидетдин, шул заманның иң абруйлы тарихчысы, аларны төркиләр дип санаган. Монголлар тарихи хроникаларда татарлардан соң берничә гасыр соңрак искә алыналар. Мәхмүт Кашгари, төрки телләр буенча зур гыйлем иясе, татарларны бары тик төркиләргә генә кертә һәм «Дәшти Татар»ны Төньяк Кытай белән Көнчыгыш Төркестан арасына урнаштыра.

Гоби чүленнән көньяктарак яшәгән күчмә халыкларны «ак татарлар» дип йөрткәннәр. Аларның күбесен төрки телле онгутлар тәшкил иткән. «Кара татарлар», шул исәптән кераитлар да, мәдәни үзәкләрдән ерак далаларда яшәгәннәр. Алар төнгелеккә арбаларын боҗра итеп тезгәннәр дә үзенә күрә бер стан корганнар. Көньяк Себернең «кыргый татарлары» аучылык һәм бакчачылык белән көн иткәннәр, аларга аксакаллар — өлкәннәр идарә иткән, аларның ханнары булмаган. Төрле татар дәүләтләре (Кытай һәм гарәп елъязмачылары шундый алты дәүләт булган дип саныйлар) барлыкка килгәнгә күрә, «татар» этнонимы политонимга әверелгән, бу атама күп кенә монгол һәм төрки телле халыкларга таралган. Һәм соңрак, Чыңгыз хан бөтен дөньяда монгол яулап алучысы буларак дан казангач та, кайбер тарихчылар аны татар дип атыйлар, этник яктан туры килмәсә дә, бу Кытай традициясенә туры килгән. Тора-бара бөтен Евразияне «Тартария» белән тиңләштергәннәр, бу урта гасырлар карталарында нәкъ шулай.

Чыңгыз хан заманындагы монголлар исә үзләрен татарлардан аерып йөрткәннәр, алар бит идарәче катлам булган, гаскәрләрнең иң өске катламын тәшкил иткәннәр, меңбашларның күбесе монголлар арасыннан сайлап куелган, әкренләп төрки телле яугирләрнең төп өлешен һәм халыкны да татарлар дип атый башлаганнар. 1236 елда Урал алды җирләрен буйсындыруның шаһиты булган венгр монахы Юлиан болай дип белдерә: «Яулап алынган барлык патшалыкларда алар үзләрендә шик тудырган кенәзләрне һәм вельможаларны шунда ук үтерәләр... Яу чыгарга яраклы гаскәриләрне һәм кешеләрне коралландырып, үзләреннән алда ирексезләп яуга кертәләр. Яу чабарга яраксызларын җир эшкәртергә калдыралар... һәм аларга үзләрен татар дип атарга кушалар». Башта ясалма политоним булган нәрсә соңыннан мәдәни һәм тел бердәмлеге белән ныгытыла. Моңа Алтын Урданың мөстәкыйль дәүләт буларак формалашуы ярдәм итә, аның мәдәнияте гаять көчле була, шуңа күрә дә ул көчсезрәк халыкларны үз орбитасына суырып ала. Калганын уртак үзаң һәм кыпчак диалектына нигезләнгән дәүләт теле эшләп бетерә, нәтиҗәдә урта гасырларның яңа бергәлеге — «татарлар», төгәлрәге «төрки-татарлар» барлыкка килә.

Татар теленең кыпчак теле белән якынаюы татарлар нигез салган һәм кыпчаклар килеп кушылган Кимәк каганлыгы кысаларында VIII — IX гасырларда ук башлана. Иң гаҗәбе: телләре төп телгә әверелгән кыпчаклар халык буларак яшәүдән туктыйлар. Әл-Гомәри «Дәшти Кыпчак» турында болай дип яза: «Борын заманда бу дәүләт Кыпчаклар иле иде, әмма аны Татарлар яулагач, Кыпчаклар алар буйсынуында булалар. Аннары алар белән туганлашып бетәләр һәм бу җирләр аларның [Татарларның] табигый һәм раса сыйфатларыннан өстен булып чыга һәм алар барысы да Кыпчакларга әверелә, гүя бер ырудан чыкканнар диярсең». Кыпчак тамырларын татарлар арасында табарга мөмкин булган кебек үк казахларның да, үзбәкләрнең дә, ногайларның да, башкортларның да һәм хәтта урысларның да (аеруча казаклар арасында) нигезен кыпчаклар тәшкил итә. Тагын бер куәтле этнос — болгарлар этносы да татарлар, чувашлар һәм славянлашкан Дунай болгарларында эреп юкка чыккан. Әмма кайбер этнослар локаль үзенчәлекләрен этнографик төркемнәр сыйфатында саклап калганнар.

Теләсә кайсы халыкның состав өлеше катлаулы һәм еш кына күп җепләр белән бүтән этносларга барып тоташа. Татар белән чувашны тамырларында болгар каны булу берләштерә. Башкортларны нугайлардан (нугай татарларыннан) «үткен аналитик акыл» гына аера ала, шул ук вакытта алар барлыкка килүдә татарлашкан маҗарлар (венгрлар) шактый роль уйнаган. Плано Карпини башкортларны маҗарлар белән тәңгәлләштергән: «башкортлар — алар бөек венгрлар («basgard id est Magna Hungaria»). Гийом де Рубрук белдерүенчә, Башкортстан халкы инде XIII гасырдан ук венгрларга аңлаешлы үз телен саклап калган. Урта гасырларның күренекле тарихчылары Җүвәйни һәм Рәшидетдин Көнчыгыш Европа венгрларын «башгирдлар» дип атаганнар. «Патша уллары башгирдларның, маҗарларның һәм сасаннарның барлык өлкәләрен яулап алганнар, аларның патшасы келаре (короле) качып киткән, җәйне Тиса елгасы буенда уздырганнар»,— дип яза Рәшидетдин венгрларны һәм саксоннарны буйсындыру турында. Кайвакыт елъязмачылар венгрлар белән бергә төрки телле кабиләләрне дә башкортлар дип атаганнар.

Татарларны һәм нугайларны совет чорында гына төрле халыклар дип саный башлаганнар, әмма әлегә кадәр Үзәк Азиядә татарларны нугайлар дип атыйлар. В.Трепавлов: «Нугай» этнонимы вәкилләре тирәюньдәге барлык халыкларның составына кергәннәр. Күршеләре нугайларны юкка гына полиэтник бергәлек дип бәяләмәгәннәр инде һәм бу этноним белән төрле этнос вәкилләрен атаганнар. Кырым ярымутравыннан читтәге далаларда яшәүче Кырым татарларының төньяк төркемен дә нугай дип йөрткәннәр; казахлар өчен *нугай* — башкортлар һәм Идел буе татарлары; башкортлар һәм казахлар өчен элегрәк вакытларда *нугай —* Себер татарлары; калмыклар өчен *иштиг мангад (*ягъни иштәк-мангытлар) — башкортлар, ә *уулун мангад* (тау мангытлары) — балкарлар һәм карачайлар һәм башкалар»,— дип яза.

Бүген генә без нугайлар белән татарлар арасында аерма күрәбез, ә бит урта гасырларда аларны бер халык дип санаганнар. Шул елларның бер урыс китабында болай диелгән: «Ул үзе (Мөхәммәт Гәрәй) Кырым татарларын яратмый башлады, әмма нугай татарларын бик ярата башлады, алары аның бик күп һәм ул аларны үзенә якынайтты һәм үзенә яхшылык эшләүчеләр дип саный». Күргәнебезчә, монда нугайларны далаларда, ягъни билгеле бер үзенчәлекле территориядә яшәүче татарлар буларак кабул итәләр. Кайвакыт татарлар белән нугайларны хуҗалык итү рәвешенә карап аерганнар. XIX гасырда хәтта Кырым бакчачысын һәм игенчесен — татар дип, ә Перекоп аръягындагы чабанны нугай дип йөрткәннәр.

Төрки халыклар үзара тугандаш кабиләләрдән җыелган. «Идегәй» эпосы түбәндәге сүзләр белән башлана:

Борын үткән заманда
Болгар белән Сарайда,
Җаек белән Иделдә,
Алтын Урда, Ак Урда —
Данлы кыпчак җирендә,
Татардан туган Нугай илендә
Туктамыш дигән хан булды...

«Төрек» этнонимы тел һәм мәдәният бергәлеге нигезендә V йөз азагында кабиләләр кушылуы нәтиҗәсендә оешкан. Этнонимның таралуы Ашина ыруыннан башлана, ул Төрки каганлыгы башында торган. Галимнәр фикеренчә, Ашина ыруы башта төрек тирәлегенә эләккән сяньбий (төрки һәм монгол кабиләләре конгломераты) чыгышлы булган. «Суйшу» кытай тарих елъязмаларында болай язылган: «Туцзюэ (төркиләрнең) бабалары Пинлянның катнаш *хуы* (һуннары) булган. Аларның ыру кушаматы Ашина. Төньяк Эй императоры Тай У-ди Цзюйцюйны (439 ел) юк иткәч, Ашина биш йөз гаиләсе белән жужуга (жужалыларга) кача. Алар Цзиньшань (Алтай) таулары итәгендә ырудан ыруга күчеп яшәгәннәр һәм тимер эшкәртү белән шөгыльләнгәннәр». Әсән-шад, «бөек ябгы» Туу һәм Бумын җитәкләгән кабиләләр төркеме 551 — 555 елларда Жуаньжуань каганлыгына җимергеч һөҗүм ясый һәм бу чорны Төрки каганлыгы барлыкка килү вакыты дип санап була.

Төркиләр яшәгән ареалларда, чыганаклардан күренгәнчә, төрле этнонимнар искә алына, әмма чынлыкта исә әледән-әле теге яисә бу ыру өстенлек итә һәм хәтта халыкка яки дәүләткә исеме дан казанган юлбашчы исеме бирелә. «Он-огуз», «докуз-огуз» этнонимнары тугыз-ун кабилә дигәнне аңлата. «Уйгур» этнонимы — шул ыру исеменнән, «карлук» шушы җирлек исеменнән килеп чыга. Хәтта күп кенә гасырлар узгач та, Алтын Урда дәверендә шундый күренешләрне күзәтергә була. Нугайлар үзләре дә исемнәрен Нугай бәк исеменнән алганнар. Алтын Урданың фанатик мөселманнары үзләрен XIV гасырда Үзбәк хан хөрмәтенә яңа исем белән «үзбәк» дип атаганнар, 1428 елда Төмән Урдадан аерылып чыга, анда Әбел-хәер хан һәм аның олысы «үзбәк халкы вә олысы» дип исемләнгән. Алтын Урда белән көрәшендә аларны Аксак Тимер кулланган. Урта Азиянең үзендә ул заманнарда үзбәкләр дигәндә, көнчыгыш «Дәшти Кыпчак»ның күчмә кабиләләрен күз алдына китергәннәр. XVI гасыр башында Исфахани бу хакта болай дип яза: «Өч кабиләне үзбәкләргә кертәләр, алар барысы да Чыңгыз хан биләмәләрендә данлыклы. Бүген берсе (шуларның) шәйбанилар... Икенче кабилә — казахлар, алар бөтен дөньяда көч-кодрәтләре һәм батырлыклары белән атаклы, ә өченче кабилә — мангытлар...». Бу очракта, В.Трепавлов фикеренчә, Себер мангытлары дигәндә мангытларга бүлеп бирелгән җирләрдәге кыпчаклар дип аңларга кирәк.

Үзбәк берлегендә Әбелхәер исән чакта ук киләчәк казахларның үзәге барлыкка килә башлаган. Габделразак Сәмәрканди 844 елда: «Вакыт-вакыт казакларга әверелгән үзбәк гаскәреннән бәгъзеләре мазандаранга киләләр һәм, бөтен җирләрне талап, кире китәләр иде». Кайчак аларны тарихи елъязмаларда үзбәкләр-казахлар дип йөртәләр. Җүчи хан улы Шәйбан үзе, тарихчысы раславынча, үзбәк дигәндә — Шәйбан олысының күчмә кабиләләрен, ә казахлар дигәндә Урда-Ичен олысы күчмәләрен күз алдында тоткан, алар берберсеннән этник яктан бик аз аерылганнар. XVI гасырда гына Әбелхәер оныгы Шәйбани хан, Сәмәрканд белән Бохараны яулап алып, тимурчылар дәүләтен буйсындырган һәм «үзбәк» исемен Урта Азия төркиләренә дә тараткан. Шул заманда ук татарлар, үзбәкләр, казахлар арасында реаль аерымлыклар барлыкка килгән.

Хәзерге дәвердә этносларның атамалары яшәү урыннарына бәйле рәвештә килеп чыга. Себердә яшәгән төрки-татарлар — «Себер татарлары», Кырымда яшәүчеләр — «Кырым татарлары», Әстерханда — «әстерханлылар», Мещера җирендәгеләр — «мишәрләр», башкорт җирендәгеләр — «башкортлар» һәм башкалар. Кайсыдыр халыкларда — «кыпчак каны» күбрәк дию белән, кайберләрендә — болгарлар йогынтысы көчлерәк дию белән, кайдадыр — хәзәрләр чагылышы тирән булу белән, бәгъзеләрендә — «угыр каны» көчлерәк булу белән килешергә дә мөмкин. Бүген гомер сөрүче төрки халыклар — шушы ук кабиләләрнең катышмасы. Дөресен генә әйткәндә, алар барысы да төрки-татар сөйләменең гаҗәеп тотрыклыгына нигезләнгән бердәм мәдәният вәкилләре.

Табигатьтә саф этнослар булмый. Һәр халыкта күп кенә кабиләләрнең һәм этносларның состав элементлары була. Садри Максуди фикеренчә, «Турыдан-туры этник, ыру яисә кабилә дәвамчылыгын, этник тәңгәллекне борынгы һәм урта гасырлар төрки кабиләләре, шулай ук урта гасырлар һәм хәзерге этник төрки берәмлекләр арасыннан эзләү бернинди уңай нәтиҗәгә китермәячәк». Шуңа күрә дә без борынгы һәм урта гасырлар тарихы турында сөйләгәндә, «татар цивилизациясе» терминына караганда «төрки-татар цивилизациясе» термины кулайрак. Мондый термин тарихны тар этник аңлатудан качарга ярдәм итә, аны объективлаштыра һәм төрки халыкларның тыгыз бәйләнешен аңлатып бирә.

Алтын Урда таркалганнан соң һәм күпсанлы төрки-татар халыклары барлыкка килгәч, территориаль аерымлыклар тагын да ачыграк чагыла башлый. Ак Урда нигезендә казахлар барлыкка килә, Үзәк Азиядә төрки телгә фарсы теле йогынты ясый һәм хәзерге үзбәк теле барлыкка килә, Кырым татарлары, төрек (угыз) мәдәниятенең күп элементларын үзләштереп, озак вакытлар Госман империясе протекторатында булалар, ә бүтән этник төркемнәр чагыштырмача изоляциядә калалар һәм локаль үзенчәлекләрен үстерәләр. Бүген аларны азәрбайҗаннар, кумыклар, балкарлар, карачайлар, нугайлар һәм башкалар дип атыйлар.

Төркиләрнең тагын да бүленеше һәм хәзерге милләтләр нигезендә яңа халыклар барлыкка килү төгәлләнгәнгә охшый. Ахыр чиктә, Русиядә 2002 елдагы халык санын алу барышында татарлардан керәшеннәрне, Себер һәм башка татарларны аерып чыгару нияте уңышка ирешмәде. Төрки цивилизацияне этник ваклауга тарих үзе нокта куйды, глобализация дә, күп кенә халыкларны инглиз-саксон мәдәнияте тарафыннан йотылу алдына китереп бастырып, вазгыятьне бик кискен үзгәртте. Хәзерге заман процессларының басымы астында төркиләр реинтеграция юлларын һичшиксез эзли башлаячаклар.

Әлегә кадәр татарларның киң катламнары да, галимнәре дә халыклар арасындагы аермаларны гына эзлиләр иде, аларны уртак сыйфатлар кызыксындырмый иде. Акыл сатулар мәгънәсезлеккә әверелә иде — кайбер авазларны әйтү үзенчәлегенә карап, үзенчәлекле диалект булу турында нәтиҗәләр ясала иде. Мондый анализның методикасы нинди мәгънәгә ия соң? Бернинди мәгънә дә юк. Без бары тик провинциаль аң рудиментлары гына, тикшеренүләрнең тарлыгы, галимнәргә республикадан читкә чыгарга рөхсәт булмау гына. Диалектлар белән фән тирәсендәге күнегүләр совет галимнәре даирәсендә генә аңлашыла, дөньяда бу

термин башка мәгънәгә ия. Лингвистика буенча безнең мәкаләләрне чит телләргә тәрҗемә иткәндә җитди терминологик шәрехләр таләп ителә. Әгәр аларны турыдан-туры тәрҗемә итсәң, чит ил кешеләре минзәләлеләр Казан арты татарларын аңламый икән дип уйлаячаклар, ә мишәрләр калган татарларга аңлаешсыз телдә сөйләшә икән дигән фикер туачак. Чит ил журналистларының һәм галимнәренең гадәти соравы шундый була: «Татар һәм башкорт телләре арасында берәр уртаклык бармы?» Җавап аларны аптырашта калдыра. Алар, бик шикләнеп, сораша башлыйлар: ни өчен соң, алайса, алар шулкадәр охшаш булгач, мөстәкыйль телләр дип аталалар? Бу — совет чорыннан калган авыр мирас. Бүген демократия күп нәрсәләр рөхсәт итә, әмма элеккедән килгән инерция үзенең йогынтысын җуймый әле. Бу зыянлы инерцияне җиңеп чыгар өчен интеллектуаллар көче таләп ителә.

Татарлыктан татар һич гарь итәрме,
Кеше үз исмене инкяр итәрме,
Татарлыкта татар угълы татармын,
Татар түгел димә — башың ватармын!

*Дәрдмәнд*

Кайчандыр кабилә, этнос, милләт-дәүләт этнологлар һәм антропологлар тикшеренүләренең төп объектлары иде. Бу төшенчәләр күпләгән процессларны аңлатып бирәләр иде. Бүген классик этнология барысын да аңлатып бирә алмый. «Без» («алар» һәм «үзебезнекеләр») «читләр» мөнәсәбәтләре тәңгәллекнең катлаулы гаммасы белән алмашына, бу исә постиндустриаль дәверне ачык чагылдыра. Дөрес, бөтен илләр дә үсешнең мондый баскычына күчмәгәннәр әле, әмма барысы да шушы процесслар орбитасында әйләнә һәм бер-берсенә уртак икътисади базар шартлары белән бәйләнгәннәр. Милләт-дәүләтләр дәвере тәмамланды.

Үз вакытында милләтләр һәм, билгеле инде, милләтчелек (Европа аңлаган уңай мәгънәсендә) Австро-Венгрия империясе, Оттоман империясе һ.б. җимерелүгә китерде. Сәбәбе гап-гади — милли икътисад байлык чыганагы буларак иң нәтиҗәлесе һәм ул территорияләр яулап алуны файдасызга әверелдерде, милләтләр яңа империяләр төзелүгә киртә булдылар. Әмма шул ук икътисади көчләр бөтендөнья базарын оештыру юлы белән милли каршылыкларны бетерергә ярдәм итәләр. Тагын шунысы бар, «сәяси һәм этник чикләр туры килгән җирләрдә җәмгыять үсештән туктый һәм милләтләр артка алып ташлана, алар башка кешеләр белән аралашудан туктаган кеше хәленә төшәләр». Тарихи күзлектән караганда, милләтчелекнең идеология буларак киләчәге юк. Глобализмның барлыкка килүе милләтчелекнең көчсезләнүен күрсәтә, дөнья буйлап экология өчен көрәшүчеләр, трансмилли корпорацияләр җитәкчеләре, финансистлар, дизайнерлар, язучылар һәм сәнгатькярләр сыйфатында планетар аң-акыл сәяхәт итә һәм моңа аралашуның заманча чаралары ярдәм итә.

Этнос — тарих күләгәсендә калган мәдәниятнең иң соңгы сыену урыны ул. Ачык мисалы — АКШтагы индеецлар резервациясе. Милләт-дәүләт исә — индустриаль дәвернең артта калуын консервацияләп кую гына ул. Дәүләт чикләре халыкның үзтәңгәллек үзенчәлеге буларак үз ролен югалта бара. Шундый дәвер килер ки, анда үзенчәлекләре беленер-беленмәс булган мәдәни конгломератлар идарә итәр. Евросоюз — халыклар бергәлегенең принципиаль яңа бергәлеге ул. Бу «европалылар» милләте түгел, бу — мәдәни конгломерат. Һәм монда бәйләү чарасы тел дә, дин дә түгел, ә либерализм. Иреккә омтылу — тарихның төп лейтмотивы, димәк, Европа башка халыклар да барачак юлдан атлый. Европада инглиз-саксон яисә пангерман цивилизацияләре өстенлек итү этник, төбәк яки хәтта чиктәш мәдәниятләргә әверелгән субэтник мәдәниятләр бәрабәренә тигезләнә.

Шушы үзгәрешләрдән чыгып, Американың «эреткеч казаны» да яңача аңлауны таләп итә, әмма ул постиндустриаль эпоха өчен яраксыз. Глобальләшү американлыларның эчке дифференциациясе процессларын көчәйтә һәм аларның этник күптөрлелеге котылгысыз бер күренешкә әверелә бара.

Милләт-дәүләтләр белән хушлашу күп кенә гадәти күзаллаулар үзгәрүне таләп итә. Русия исә милләт-дәүләт буларак оеша алмады. Ул империя буларак яшәде һәм советлардан соңгы киңлекләрдә дәүләтләр барлыкка китергән милләтләр басымы астында җимерелеп төште. Бүген Русиялеләрне милләт буларак җыю омтылышы файдасыз эш, чөнки индустриаль эпоханың сәяси процессларын кире кайтару мөмкин түгел. Дәүләт чикләре эчке базар барлыкка китерми, тел мәсьәләсе һәм мәдәният вазифасы бүген бөтенләй башкача. Русия Федерациясендә этник дифференциацияне нивелирлау да мөмкин түгел, мәдәни күптөрлелекне хуплаучы заман килде. Мондый шартларда «Русиялеләр» милләтен-дәүләтен оештырырга омтылу көймә бата башлагач кына агымга каршы йөзәргә тырышу белән бер. Әгәр Русиядәге аз санлы халыкларның үзбилгеләнүгә хәтта көче җитмәсә дә, икътисад, халыкара сәясәт, мәдәниятләр үсеше иҗтимагый тормышны милләтләштерүдән читкә этәрәчәк. Ул инде күптән мозаиканы хәтерләтә, ә төбәкләр икътисады үсә барган саен, күптөрлелек колач җәячәк. Үзәктән килүче унификацияләнгән карарлар анахронизмга әйләнәчәк. Шуңа күрә дә Русия икътисады үзәкләшүдән качачак. Шуннан соң ук бюджетка, салымнарга,

җиргә, энергия чыганакларына, табигать байлыкларына контроль үзгәрәчәк. Бу бик авыр барачак, әмма бу — котылгысыз гамәл. Бүген үк инде мәнфәгатьләр һәм теләкләр күптөрлелеге артканнан-арта бара. Климат һәм география масштаблары, икътисади ихтыяҗлар һәм ил чикләрендәге вазгыять, этник канәгатьсезлек, мигрантлар проблемасы һәм башкалар — болар барысы да мәдәнияттәге, диндәге, сәнәгатьтәге стандартлаштыруга китереп суга. «Милләтчелек югары технологик мәгънәсендә төбәкчелеккә әверелә,— дип раслый Элвин Тоффлер.— Эреткеч казаннарның басымы этнослар басымы белән алышына. Массакүләм мәдәнияткә алмашка килүче тирәлек аны массалашудан азат итә. Мондый үсеш энергия формаларының барлыкка килүче күптөрлелегенә һәм массалардан тыш җитештерүгә даими туры килә». Гәрчә аның киләчәктә чәчәк атуын карарлар кабул итүне унификацияләү белән түгел, нәкъ менә шул күптөрлелек белән бәйләргә кирәк булса да, Русия һаман моңа каршы тора.

Милләт белән хушлашу халыкара мөнәсәбәтләрне дә үзгәртә. Берләшкән Милләтләр Оешмасы милләт-дәүләтләр берлеге буларак сакланып кала алмаячак, чөнки яңа чынбарлыкка туры килми, ул әгъза-дәүләтләрнең генә түгел, ә дәүләтчелеге булмаган халыкларның да мәнфәгатьләрен исәпкә алырга мәҗбүр булачак.

Этнология һәм антропология турындагы Русия фәне терминнарны аңлауда гына түгел, чынбарлыкны кабул итүдә дә буталып бетте, күрәсең. Русиянең төп этнологы В.А.Тишков «милләт» атамасын да, этнос төшенчәсен дә бөтенләй кабул итми, милләт фәнни категория түгел һәм ул фән һәм сәясәт теленнән төшеп калырга тиеш» дип саный. Милләтчелек, миллилек һәм хәтта дәүләт — болар бар да аның өчен ясалма нәрсәләр. «Яңартылган анализ өчен,— дип яза ул,— «милләт-дәүләт беткәнне» көтеп ятарга кирәкми, чөнки милләт-дәүләт — шул үк «чынбарлыкка» карамастан, үзгәртеп коруны таләп итүче акыл метафорасы». Халык санын алу күрсәткечләре аныңча «халыкның үзенә карата шартлылык кына». Аның фәнни эзләнүләре асылын аңларга тырышу гаять кыен. В.Тишков хезмәтләрен укыганнан соң, Геллнер, Барт кебек Көнбатыш белгечләре идеяләре начар бәян ителә дигән тәэсир кала. Геллнер бит катлаулы нәрсәләрне гади итеп язган, В.Тишковта исә гади әйберләр дә бик нык буталган. В.Тишковта боларның барысы да бер идеягә буйсына: барлык этник, милли, дәүләти күренешләр — ниндидер милли активистлар манипуляциясе генә. Үзенең манипуляция теориясе нигезендә В.Тишков чынлыкта исә шуның белән үзе үк шөгыльләнергә җыена. 2002 елгы халык санын алу алдыннан миңа Русия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институтының Гыйльми советында катнашырга туры килде, анда керәшеннәр мәсьәләсе күтәрелгән иде, керәшеннәрне «ирекле», «мөстәкыйль», «җәберләнгән» халык дип белдерделәр һәм миңа анда гыйльми чыгышлар урынына бик күп кирәкмәгән нәрсәләр ишетергә туры килде. Гыйльми совет кысаларындагы митинг иде бу. Бернинди анализ да юк, саф манипуляция генә. Андагы кешеләр, татарча бер кәлимә сүз белмәгән килеш, «керәшен теле»нең мөстәкыйль яшәве турында фикер йөрттеләр. Бу тамашага каршы сүз дә әйтеп булмый иде, чөнки ул үзе этнологиягә ясин чыгу иде. Фаҗигагә каршы көрәшмиләр. «2002 елгы халык санын алуга әзерлек барышында,— дип яза В.Тишков,— экспертлар һәм статистиклар арасында бәхәсләр кузгалды һәм билгеле бер буталчыклык килеп чыкты». Моңа аптырыйсы юк, бу буталчыклыкны ул җитәкләгән институт тудырды лабаса. Татарча сөйләшүче нугайбәкләрне мөстәкыйль халык буларак язуга мин каршы чыккач, тиешле графада нугайбәк теле дип үзгәртеп язылган булып чыкты. Берәүнең «җитез» кулы белән тагын бер тел дөньяга килде — нугайбәк теле! Әгәр Себердә яшәүче урысларны Себер телле аерым халык дип язсалар, урыслар ни әйтер иде икән? В.Тишков белән республикалар, халыклар, башка галимнәр килешмәскә мөмкин, ул чакта В.Тишков аларны дилетантлар дип атый. Ул Н.Бердяев хезмәтләрен дә мәгърифәтчел публицистика дип кенә җибәрә, «анда сүз нәрсә турында: дәүләтләр турындамы, сәяси яисә этномәдәни бергәлекләр турындамы — аңлашылмый», янәсе. Тагын болай ди: «Н.А.Бердяев «милләт» сүзен «халык» сүзенә алмаштырырга тәкъдим итә, әмма бу аның фәлсәфи публицистикасын эмоциональ җитешсезлектән коткармый». Николай Бердяев идеяләренә төрлечә карарга мөмкин. Мәсәлән, ирек идеясен Ходайны саф христианча эзләүләр белән бәйләүне аңлау минем өчен бик кыен, әгәр Н.Бердяевны урыс җанын, урыс психологиясен, халык характерының тирән катламнарын өйрәнүче философ буларак бәяләсәң, аның «Русская идея» исемле бер кечкенә хезмәте генә дә Русия Фәннәр академиясенең Этнология һәм антропология институтының соңгы елларда басылып чыккан барлык фәнни хезмәтләренә торырлык. Н.Бердяев, һичшиксез, урыс философиясенең иң югары ноктасы, ә В.Тишков хезмәтләре — кайчандыр күренекле булган урыс этнографиясенең кояш баешы. Ул — этнология тирәсендә манипуляторлар, сәяси технологлар барлыкка килү дәверенең үзенчәлекле билгесе. Әмма халыклар мондый манипуляцияләрдән бәйсез рәвештә яши бирәләр. В.Тишков: «Русиядә 2002 елгы халык санын исәпкә алу үзенең төп миссиясен — дәүләт өчен халык булдыруны үтәмәде»,— дип үкенеч белдерде. Димәк, халыклар үзләре өчен яшәмиләр, алар дәүләткә хезмәт итәләр, әмма тарихтан бит башкасы мәгълүм: дәүләт үзе — халыкның яшәү рәвеше.

Милләт-дәүләт төзеп өлгермәгән һәм яңа тенденцияләр йогынтысын үзендә татып өлгергән татарларның конфигурациясе нинди булыр соң? Татарларның стратегиясе үткәндәгегә охшамаган катлаулы культурологик процессларны аңлатудан килеп чыгарга тиеш. Милләт корылышы процессларының нindидер бер аналогиясе хәзер Татарстанда да бара, анда урыс-татар симбиозы псевдомилләткә охшаган, ягъни ике теллелек номиналь рәвештә булса да нормага әверелеп бара, ахыр чиктә, үсеп килүче буын өчен өстенлекле нәрсәләр бар: уртак икътисади мәнфәгатьләр, тотрыклыкка омтылу. Боларның барысын да халык хуплый бит. Болар бар да, социологик тикшеренүләр раславынча, татарстанлылар психологиясен формалаштыра.

Татарстан бер үк вакытта татар халкының үзәге буларак сакланып калачак, татарларның локаль субкультуралары, сөйләмнәре исә төбәк аерымлыгы буларак сакланып калачак. Бу — гадәти һәм табигый нәрсә, мәдәни интеграция көчәйгән саен, локальләшү дә көчәячәк. Себер татарлары телен булдырырга омтылу, керәшеннәр хәрәкәте, башкорт милләтчелеге — болар бар да хөрлек шартларында шәхеснең үз-үзен раславының табигый күрсәткечләре. Идеологик басым юкка чыгуга, кешеләр үзләренең аерымлыклары турында уйлана башладылар. Бу да бик табигый. Шәхес формалашу да шулай ук бара, башта ул үзенең уникальлеген тоярга, аннары инде бергәлеген сизәргә тиеш. Шуңа күрә дә Себердәге татарлар үз үзенчәлекләрен эзли башладылар, керәшеннәр белән мишәрләр — үзләренекен. Әмма бу вакытлы күренеш, ул аңлылыкның югарырак дәрәҗәсенә күчү чоры гына, мондый дәрәҗәдәге кешеләр аерымлыклары хакында түгел, ә бәлки халык белән, республика, ил белән кушылу турында, төрки һәм мөселман дөньясындагы, ахыр чиктә, җир йөзендәге урыннары турында уйлана башлыйлар. Шул чакта локаль аңлылык дәрәҗәсен алмаштырмый һәм юкка чыгармый торган интегратив аң барлыкка килә. Интеграция берничек тә унификация дигән сүз түгел, унификация — кирәксез, зарарлы һәм мөмкин булмас нәрсә ул.

Тагын бер чыгарылма тезисның мәгънәсе түбәндәгечә: панславянизм кебек үк пантюркизм яки төрки глобализм да мөмкин түгел, чөнки боларның вакыты узган инде. Пангерманизм Лютерга рәхмәтле булырга тиеш, урыслар исә ассимиляциягә ышанганнар, нәтиҗәдә украиннар һәм белоруслар килеп чыккан, гәрчә этник үзенчәлекләрне саклап, уртак әдәби тел нигезендә немец тибындагы бергәлек төзи алган булырлар иде. Хәзер инде ул мәйдан поляклар кулында. Әгәр урыслар украиннар белән уртак тел тапмасалар, тегеләре полякларга китәчәкләр, ә болгарлар македонлылар, серблар һәм черногориялеләр белән берләшәчәк.

Пантюркизмның мөмкин булмавы билгеле бер төрки бердәмлек идеясен юкка чыгармый, шул ук вакытта уртак мәнфәгатьләр, территория, мәдәни симбиоз җирлегендә татар-урыс теләктәшлеге туу ихтималы да бар. Шулай ук чиктәш субкультуралар белән бергә үзенчәлекле төрки-татар конгломераты да оешырга мөмкин, ул исә үз чиратында тагын да киңрәк төрки конгломерат орбитасына килеп кушылырга мөмкин. Чиктәш тел һәм мәдәни үзенчәлекләр үзара мөнәсәбәтләрнең күпләгән күчеш рәвешләрен тудырачак, әмма ул татар-башкорт мөнәсәбәтләре кысаларында түгел, нугай-, балкар-, карачай-, кумык-, Кырым татарлары-, казах-, кыргыз-татар мөнәсәбәтләре кысаларында булырга мөмкин. Билгеле бер мәдәни бәйләнешләр, үзбәкләрне, азәрбайҗаннарны, төрекләрне, уйгурларны да кертеп, тагын да киңрәк төрки конгломератта барачак.

«Татар» этнонимы язмышның төрле борылышларын кичерде: кабиләләр төркеме атамасыннан ул төркиләр синонимына әверелде, аннары Алтын Урда халкының үз-үзенә кушкан атамасына әйләнде. Озак вакытлар татарларны суперэтнос дип санаганнар. Англия илчесе Дж.Флетчер 1589 елда «Русия дәүләте турында» язмалар иҗат итә, анда ул татарларга нугайларны гына түгел, чирмешләрне дә, мордваларны да, чиркәсләрне дә, щелкалларны да, пермякларны да, самоедларны да кертә. Европалылар күзаллавынча, Кырым ул — «Кече Татар иле», Идел аръягыннан Көнчыгышка таба исә «Бөек Татар иле» җәелеп ята. Хәтта Петр I заманнарында да карталар шул ук атамалар белән чыгарылган. «Татар иле» Евразия белән тәңгәлләштерелгән. Ниһаять, «татарлар» термины XX гасырда «Идел буе» (географик мәгънәдә түгел, этник мәгънәдә, моңа мишәрләр, керәшеннәр, Әстерхан, Себер татарлары һәм башка татарлар кертелә) һәм Кырым татарлары буларак ныгып кала.

«Татар» этнонимының үз катлаулы тарихы булганга күрә, аның төрле дәверләрдә тарихи хроникаларда нинди конкрет эчтәлеккә ия булуын онытмаска кирәк. Бүгенге татар халкына килгәндә исә, аның теле һәм мәдәнияте барлыкка килүгә көнбатыш һуннары һәм, мәсәлән, болгарлар, Төрки каганлык, Алтын Урда һәм тагын Русия составындагы этногенез процесслар зур йогынты ясый. Хәзерге татарларны болгарларга яисә VII гасыр татарларына гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде, әмма тарихыбызны Аттила яки Батый хан походларыннан аеру да мөмкин түгел. Татарларга XX гасырда югары мәдәният үсешенең заманча институтлары да зур йогынты ясый, шуңа күрә дә соңгы йөзьеллык үзенең йогынтысы буенча берничә гасырга тиң.

Татарлар тарихы төрки халыклар белән генә түгел, фин-угыр, билгеле инде, урыс халкы һәм башка халыклар белән дә тыгыз бәйләнгән, бу хәл этнос барлыкка килүнең аңлатмасына тагын бер фактор өсти.

## Тел

*Совет чорында татар мәктәпләре, татар гәзитләре ябылды, татарча өйдә генә яисә үз ишләрең арасында гына сөйләшергә мөмкин иде. Зыялылар вакыт-вакыт әдәби кичәләргә җыелалар иде, бу кичәләр һәрчак Габдулла Тукайның «Туган тел»-ен җырлау белән тәмамлана иде. Бөтен зал, тоталитар системага каршылык белдереп, аягүрә басып, татар гимнына әверелгән «Туган тел»ен суза иде.*

*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*
*Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.*

*Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,*
*Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.*

*И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең*
*Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.*

*И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам,*
*Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!*

Төрки-татар цивилизациясе гасырлар төпкелендә, Азия төпкелләрендә барлыкка килә. Төрки сөйләмнәрдә аралашучы халыкларны төрлечә атыйлар, әмма аларның уртак теле әллә кайчан, һуннар державасы барлыкка килгәнче үк оешкан. Сергей Кляшторный болай дип яза: «Төрки телле кабиләләр нигездә Үзәк һәм Эчке Монголиядә таралып яшәгәннәр: Байкалдан алып Ордоска кадәр. Тел дифференциациясе процесслары бик катлаулы барган һәм бөтен өлкәләрдә дә бертөрле булмаган; төрки һәм монгол кабиләләре күп кенә территорияләрдә катнаш яшәгәннәр; безнең эрага кадәр II гасыр башына хәтле иран телле юэчжилар күбрәк яшәгән Көнбатыш һәм Үзәк Монголиядә төркиләр шулар белән ут күрше булганнар». Тел — мең еллардан соң да мәдәният алмашын гаҗәеп рәвештә саклап калучы бәйләгеч буын ул.

Беренче карашка һуннар, борынгы төркиләр, кыпчаклар, монгол-татарларның күчмә тормыш белән яшәве, бары тик терлекчелек белән шөгыльләнүе ап-ачык кебек. Әмма әгәр төрки телнең үзәгенә күз салсаң, төркиләрнең баштан ук игенче дә, һөнәрче дә, сәүдәгәр дә булганнарын аңлыйсың. Татарларда борынборыннан үткәрелеп килгән Сабан туе һәркемгә мәгълүм. Русиядә ул иң популяр бәйрәмнәрнең берсе санала. Бу бәйрәм бик борынгы һәм исламга кадәр үк булган. «Сабан» — игенчелек коралы, борынгы төркиләрдә ул «сапан» рәвешендә яшәгән («сапмак» — өзү, ерту дигән сүздән). «Бодай», «арпа», «тары» сүзләре кебек саф төрки сүзләр барлык төрки сөйләмнәрдә дә бар. Димәк, төркиләрнең бабалары игенчеләр дә булган. «Арык» сүзе дә гомер-гомергә төрки сүз. Димәк ки, төркиләрдә борын заманнарда ук игенчелектә сугару эшләре алып барылган. «Ат», «сыер», «угыз» яки «буга» (үгез) шулай ук чыгышы белән төркиләрнеке. «Алтын», «көмеш», «бакыр», «тимер» сүзләре дә барлык төрки-татар сөйләмнәре өчен уртак, башкача әйткәндә, төркиләр элек заманнардан ук — тел калыплашкан дәвердә үк — металл кулланганнар һәм һөнәрчеләр булганнар.

Төркиләр формалашкан чакларында ук, мөгаен, игенчелек белән күчмәлекне бергә алып барганнардыр һәм соңыннан гына аның кайбер кабиләләре саф күчмәләргә әверелгәндер. «Күчмәлек,— дип яза Лев Гумилев,— өч мең еллап хөкем сөргән дөньякүләм күренеш. Ул кешенең үзгәрүчән табигать тирәлегенә яраклашу ысулы буларак барлыкка килгән һәм шул ук сәбәпләр аркасында хәзер безнең күз алдыбызда юкка чыга». Тарихның климатның глобаль үзгәрешләренә бәйле билгеле бер чорында (төгәлрәге — безнең эрага кадәр I меңьеллыкта) кайбер кабиләләр күчмә яки ярымкүчмә тормышны сайлаганнар, әмма телләрендә борынгырак катламнар да сакланып калган. Төрки сөйләмнәрдә йорт һәрвакыт, тирмәдән аермалы буларак, даими торак урынын белдергән. «Чатыр» — вакытлы торак урыны, аны күчмә төркиләр үзләренең җәйләү урыннарында корганнар. Йорт — утрак төркиләрнең даими яшәү урыны. Йорт тирәли урнашкан корылмаларны борынгы төркиләр «bark» сүзе белән белдергәннәр. «Барак» сүзе урыс телендә әлегә кадәр сакланып калган.

Гәрчә ислам кабул иткәннән соң телдә гарәп сүзләре, ислам нормалары өстенлек итсә дә, иң югары әхлакый кыйммәтләр дә төркиләрнеке. Башкача әйткәндә, төркиләр алга киткән халык буларак бик борынгы заманнарда оешканнар. Садри Максуди язганча, «төрки телнең гомуми байлыгы төркиләрнең инде тарихкача заманнарда ук мәдәният үсешендә шактый югары дәрәҗәгә ирешүен күрсәтә. Мәгънәви тамырларның байлыгы җәһәтеннән караганда, төрки тел — дөньядагы иң бай телләрнең берсе».

Борынгы төрки цивилизациясенең югары кимәлдә булуына тагын бер дәлил бар: төркиләр VI йөзнең икенче яртысында үз алфавитларын уйлап чыгаралар, соңыннан ул рун алфавиты дип атала. Дж.Клосон исәпләвенчә, надан төркиләр язма тамгалар системасын үзләре уйлап табарлык хәлдә булмаганнар, алар

хәтта согд алфавитын төрки телгә яраклаштыра да алмаслар иде. Моны аларга, имеш, борынгы төрки телне әйбәт белгән, культуралы согдлар эшләп биргәннәр. Олжас Сөләйманов исә, мондый хәлнең булуы мөмкин түгел, ди. «Борынгы төркиләр алфавитның кайбер хәрефләрен күчерсәләр дә,— дип яза ул,— согдлардан түгел, ә бәлки хәрефләре йомры булмаган, сызыкчыл, почмакчыл булган әлифбадан күчергәннәр. Мондыйлар исә безнең эрага кадәр I меңьеллыктагы Алгы Азиядә (финикий һәм арамей язуы) һәм Борынгы Скандинавиядә (рун язуы, килеп чыгышы — безнең эрага кадәр I меңьеллыкның уртасыннан алып безнең эраның I меңьеллыгы азагына кадәр дип фаразлана) булган. Әмма төркиләр язуны беренче мәртәбә шушы халыкларның берәрсеннән белгәннәр дип расларга ярамый...» Иң дөресе, мөгаен, борынгы төркиләр, согд алфавитын нигездән үзгәртеп, аларның язу үрнәкләрен үзләренә яраклаштырганнардыр: «а) кайбер тамгаларның курсив язылышы аерып язуга алмаштырылган; б) төркиләрдәге ыру тамгаларының һәм идеографик символларның рәвеше йогынтысында, шулай ук, мөгаен, фактура (таш, агач, металл) йогынтысында согд хәрефләренең шома, йомры язылышы геометрияләштерелгән язылышка алмаштырылгандыр; в) согд һәм төрки телләрнең фонетика системасы төрле булганга күрә, согд алфавитының барлык тамгалары да кабул ителмәгән, охшаш согд хәрефләренең фонетик символикасы гына алынган; шуның белән бергә рун алфавиты согд язмасында булмаган яңа тамгалар белән баетылган, алар өлешчә — идеографик, өлешчә — хәреф рәвешендә». Шулай итеп, төрки рун язуы бөтенләй яңа оригиналь язмага әверелгән. Ташлардагы, кәгазьләрдәге һәм кыялардагы язулар бу язуны белүчеләрнең шактый күп булуын күрсәтә. Рун язуы дини, эшлекле, хәрби өлкәләрдә, халык авыз иҗатында һәм әдәби язмаларда да кулланылган.

> *«Хәйлә белән арыслан аулап булса, көч белән тычкан да тотып булмый»; «Утсыз төтен булмый, кимчелексез егет булмый»; «Ялгышмасалар — зирәклек кирәк түгел, адашмасалар — озатучы кирәк түгел. Ялгышмаган язучы, адашмаган озатучы булмас».*
>
> *Борынгы төркиләрнең мәкальләре*

Рун алфавиты белән язылган әдәби ядкярләр барлык төрки халыклар өчен дә уртак. «Рун язмалары теле — VII — X гасырларда үз телләрендә һәм диалектларында сөйләшүче төрле төрки кабиләләр — угызлар, уйгурлар, кыргызлар, кимәкләр һәм башкалар аңардан файдаланган бердәм һәм стандарт әдәби тел булган,— дип яза Сергей Кляшторный.— Рун язмаларының уртак язма әдәби теле стилистик бердәйлеккә һәм тасвирлау чараларының тотрыклыгына ия, бу аеруча урхун ядкярләрендә күренә. Ядкярләрнең теле һәм әдәби кануны уртак булу борынгы төрки кабиләләр арасында үзара тыгыз бәйләнешләр булуын раслый һәм аларны икенче бер халыкның тел һәм әдәби мирасы дип карарга омтылуларны юкка чыгара». Болай дип раслау ул заманнарда тоташ бертөрле этнос булуны күрсәтми, билгеле. Әмма VII гасырда ук инде төркиләр төрле кабиләләргә аңлаешлы бердәм язма телгә ия булганнар. Бу аларның күтәрелү факторларыннан берсе булган.

Урхун ядкярләреннән күренгәнчә, төрки тел йөз ел эчендә бик аз үзгәреш кичергән. Олжас Сөләйманов бу күренешне «төрки сүзнең, төрки телнең феноменаль консерватизмы» дип атый. Төрки сөйләмнәрнең тотрыклыгы һәм якынлыгы аларның алга киткән тел буларак борынгы заманнарда ук оешуы нәтиҗәсе. Н.С.Трубецкой, төрки телләрнең охшашлыгын аңлатып, болай дип язган: «Һәр телдә аның тарихы дәвамында шушы тел кичергән һәм телнең үз тарихи үсешенә бәйле механик үзгәрешләр нәтиҗәсендә котылгысыз рәвештә «ялгышлар» һәм «искәрмәләр» барлыкка килә: тел үсешенең теләсә кайсы борынгырак чоры өр-яңа чоры белән чагыштырганда «дөресрәк». Әмма төрки телләрдә җанлы сөйләмнең аң төпкелендәге схематик законнарга буйсыну рухы шулкадәр көчле ки, бу рух тарихи процессларның җимергеч йогынтысын бөтенләй диярлек нейтральләштерә; шуңа күрә дә төрки телләрнең хәзерге грамматикалары «искәрмәләрне» белмиләр (яисә белмиләр диярлек), һәм шуңа күрә дә хәзерге төрки телләр шулкадәр бер-берсенә охшаган».

Төркиләр бер үк вакытта ике чирдән интеккәннәр: беренчесе — мәмләкәтчелек (державачылык) сәясәте, үзәкләштерелгән зур империяләр коруга омтылыш булса, икенчесе — кабиләләр арасындагы таркаулык. Төрле чорларда төрлесе өстенлек алган. Шул җирлектә төрки телнең диалектлары һәм сөйләмнәре барлыкка килгән. Бу төркиләрнең генә үзенчәлеге диярга ярамый, билгеле. Бөтен кешелек дөньясы шул юлдан бара. Кемнәрдер империяләр төзи, ә икенче берәүләр аларны җимерә. Бу объектив процесс булганга күрә, җирле мәдәниятләр гомумтөрки мәдәният үсешенә көч-куәт өстәгәнне аңлап, аның белән килешергә генә кирәк, әмма җирле үзенчәлекләрне абсолютлаштыру һәм төрки телләр арасында диварлар кору да хата булыр иде. Британия милләте бар, шул ук вакытта америкалылар да, австралиялеләр дә, яңа зеландиялеләр дә бар. Болар, бәхәссез ки, төрле милләтләр, әмма алар барысы да инглиз телендә сөйләшәләр, бер үк мәдәниятне якын итәләр, ни генә булса да, сөйләмдәге, әдәбияттагы, җирле гореф-гадәтләрдәге аерымлыклар аларга комачауламый, киресенчә, инглиз-саксон цивилизациясен бөтен дөнья мәдәниятендә өстен

итеп, баета гына. Әгәр инглизләр һәм американлылар уртак мәдәният даирәсен татарлар белән башкортлар кебек бүлгәли башласалар, инглиз теле бөтендөнья теленә әверелмәс иде.

Тагын да гаҗәбрәк мисал — немец телендә сөйләшүче халыклар. Австриялеләр, баварлар, саксоннар, швабәлар, швейцарлылар һәм башкалар бер-берсеннән шулкадәр аерылып торган диалектларда сөйләшәләр ки, без аларны һичшиксез аерым телләр дип санар идек — татар һәм төрек телләре бер-беренә мең өлеш якынрак, казах, кыргыз, уйгур телләрен әйтәсе дә юк инде, аларны аңлар өчен татарга тылмач кирәкми. Шуңа да карамастан баварлар һәм саксоннар, австралиялеләр һәм швейцарлылар бер үк әдәби телдә язалар. Әгәр үзләренең уртак мәдәни киңлекләреннән баш тартсалар һәм голландлар сыман үз диалектлары нигезендә мөстәкыйль тел булдырсалар, алар глобальләшү чорында зәгыйфьләнеп калырлар иде.

Кырым кенәзе Исмәгыйль Гаспралы үзенең дус-ишләре ярдәмендә XIX гасыр башында беренче татар газетасы «Тәрҗеман»ны чыгарырга рөхсәт алган. Ул үзе уртак төрки тел эшләгән һәм аның газетасын төрки дөньяның төрле почмакларында яшәүче зыялылар укыган. Әмма газета белән бергә тел үзе дә гаип булган. Аннан соң бик күп татар газеталары чыга, әмма шуларның берсе дә «төрки» телдә түгел. Кайвакыт матбугат теле гади халыкка аңлашылмый, әмма ул гомумтөрки түгел, ә татарча. Гаспралының экспериментлы уңышсыз булып чыккан.

Гомумәдәби немец теле Лютер тәрҗемә иткән Библия нигезендә барлыкка килгән. Нәкъ менә шулай ук Коръәндәге гарәп теле дә Гарәбстан ярымутравының, Төньяк Африканың һәм Азиянең төрледән-төрле кабиләләре өчен гомумәдәби телгә әверелгән. Әгәр заманында Коръәннең төрки-татар теленә тәрҗемәсе булса, ул да, бәлки, шундый ук вазифаны үтәгән булыр иде. Әмма ләкин болай булып чыкмаган шул. Муса Бигиев Коръәннең татарчага тәрҗемәсен бастырып чыгарырга тырышып караган, тик, язмыштыр инде, Госман империясенең мөфтие генә түгел, хәтта татар имамнары да моңа каршы чыккан. Русия хакимияте әлеге мәсьәләдә руханиларны бик теләп яклаган. Ислам реформациясе Идел буе һәм Кырым татарларына гына кагылган, аның да барлык катламнарына түгел, шуңа күрә дә Лютер тәҗрибәсен кабатлау мөмкин булмаган.

Бүген ясалма төрки тел оештырып маташуның мәгънәсе юк, шул ук вакытта бер генә төрки диалект та, бер генә төрки сөйләм дә (төрек телен дә кертеп) өстенлек алмаган. Һәр ил, һәр халык үз үсеш юлын сайлаган.

Глобальләшү чорының өстенлекләре дә, милли мәдәниятләргә зыяны да бар. Глобальләшүне нәтиҗәләре буенча Европа Реформациясе чоры белән чагыштырырга мөмкин, ул чакта яңа эрага нигез салучы басма китап дөнья күргән. Әмма бүген шуңа охшаш вазифаны басма китап түгел, Интернет башкара. Гәрчә төркиләр әле элеккеге чорның азагына барып җитмәсәләр дә, яңа Реформация чоры киләчәк әле.

Кеше виртуаль дөньяда торган саен күбрәк яши бирә, ул аның чын тормышына гаять зур йогынты ясый. Киоскка газета алырга барасы юк, ул Интернетка тизрәк килеп җитә, әйберләрне электрон почта аша сатып алырга мөмкин; теләсә нинди китапханәдән куәтлерәк зур-зур мәгълүмат системалары барлыкка килде, алар ярдәмендә укырга гына түгел, күрергә дә, ишетергә дә мөмкин, хәтта башка юллар белән ирешү мөмкин булмаган нәрсәләрне дә. Виртуаль музейга кереп, аның залларын, рәсемнәрен, экспонатларын карап була, үзеңә ошаганнарын кәгазьгә бастырып алырга да мөмкин. Якындагы елларда компьютер телевизор да, видеотелефон да, университет та, эш урыны да булачак. Иң алдынгы фирмалар виртуаль коллективлар булдырачак. Һәм бу экзотика түгел, бу — гомуми ихтыяҗ һәм ул инде ишегебезне шакып тора.

Глобальләшүнең татарлар өчен дә үз өстенлекләре бар. Русия һәм БДБ илләре буйлап чәчелеп яшәгән халыкны гадәти коммуникация чаралары ярдәмендә бергә җыю бик кыен. Интернет һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары моны чагыштырмача очсыз һәм нәтиҗәле башкарырга ярдәм итә. Бу безне коткарачак. Нәкъ менә глобальләшү татар халкын саклап калачак. Интернет аша татар мәдәнияте, кайда яшәвенә карамастан, һәркем өчен ачык булачак. Татарлар, аз чыгымнар тотып, чикләрсез, административ киртәләрсез мәгълүматлашу чарасына ия булдылар.

Глобальләшүнең куркыныч якларын күрмәскә тырышу да дөрес булмас иде. Галимнәр фикеренчә, йөз елдан соң өч тел: инглиз, испан һәм кытай телләре өстенлек итәчәк. Калган телләр вазифалары ягыннан җирле булып калачак. Мөгаен, күп кенә телләр, иң гади, иң уңай дип санап латин графикасына күчәр. Глобальләшү милли мәдәниятләр аермасын бетерә, аларга инглиз-саксон рәвешләрен көчләп тага. Глобальләшү кешене иллюзияләр дөньясына җәлеп итүче субкультураны сәнәгатьчә җитештерү булып тора. Бар да бер үк нәрсәләр укый, бар да бер үк әйбер тыңлый, бар да бер үк вакыйгалар турында гәпләшә, бертөрле уйлыйлар, джинсы киеп йөриләр, чипсы ашыйлар. Глобальләшү өчен кулланучыларның бертөрле массасы бар. Әмма дөнья — супермаркет түгел. Глобальләшүгә каршы җавап йөзеннән этник, дини, төбәк үзенчәлекләре үсешкә омтыла. Дәүләтләргә трансмилли корпорацияләр һәм халыкара оешмалар кулы белән астан да, өстән дә басым ясала, шул ук вакытта трансмилли актерлар демократиядән читтә калалар, аларны сайламыйлар, әмма нәкъ менә алар халыкара һәм милли сәясәтне билгелиләр. Милли дәүләт яңа юнәлешләр

басымыннан көчсезләнә бара. Хезмәт күрсәтүләр һәм товарлар либеральләшкән базарга чыктылар һәм мәдәният үсешенә дәүләт ярдәме кимегәннән-кими бара. Дәүләтләр һәм халыклар, үз үзенчәлекләрен коткарырга омтылып, массакүләм ассимиляциядән саклану юлларын эзлиләр.

Инглиз-саксон тарту көченнән гайре дөньяда тагын берсе барлыкка килде, ул да булса — шундый ук ассимиляциячел тарту көче — Кытай. Көньяк-Көнчыгыш Азия аның көч-кодрәтен үзендә җитәрлек дәрәҗәдә татыды инде. Зур эчке потенциал туплаган әлеге гаять борынгы культураның теләсә нинди халыкны һәм теләсә нинди илне демографик ассимиляцияләргә хәленнән килә. Хәтта Һиндстанда 150 миллион мөселман конфессиональ азчылык дип санала. Ә Кытай өчен бу — статистик төгәлсезлек кенә. Уйгурларны да кытайлар «йотарга» мөмкин.

Гарәп дөньясына яисә гарәп мәдәниятенә нигезләнгән мөселман дөньясы да үсеш потенциалын җуйды. Ул — бары тик нефть запасларының зур чаны гына. Аның фонында чит телле дөнья хәрәкәтчәнрәк күренә, чөнки католицизм контрреформация барышында яңарыш кичерде. Аның географиясе Кытай экспансиясенә каршы торыр өчен уңайлы, Төньяк Америка экспансиясе исә ике яклы таяк булып чыкты. Латин Америкасы халкы АКШка тулды һәм испан теле чынлыкта илнең көньягында яки Калифорниядә генә түгел, Вашингтон һәм Нью-Йорк кебек зур шәһәрләрдә дә икенче дәүләт теленә әйләнде.

Бу җирлектә панславянлык һәм пантюркизм балалар уенчыгы сыман гына тоела. Панславян идеологиясе — бөтенләй буш нәрсә. Католиклар һәм Европаның бер өлеше булган поляклар гомер-гомергә урысларның көндәшләре булдылар. Чехлар һәм словаклар, алай ук актив булмаса да, шул ук миссияне башкардылар. Урысларның гомерлек аркадашлары — серблар һәм болгарлар Германиянең көчле йогынтысын тоеп яшиләр. Германия көнчыгыш җирләрен үзенә яраклаштырганнан соң славян дөньясыннан булган күршеләренә керешәчәк, күршеләре исә словеннар, хорватлар, чехлар, словаклар артыннан бай, тотрыклы һәм техника ягыннан алга киткән дөньяга рәхәтләнеп барып керәчәкләр. Озакламый Украинаның да чираты җитәр.

Пантюркизм исә Русиянең көчсез һәм интеллектуаль яктан ярлы чиновниклары кулында карачкы булып кала бирә. Төркиләрнең үзләре өчен бу интеллектуалларның тар даирәсендә сөйләшү темасы гына булып кала, халык аны аңламый да, белми дә һәм белергә тели микән әле. Славян дөньясы да, төрки дөнья да бөтендөнья глобальләшүен каршыларга әзер түгел.

Язмышым, рәхмәттән башка
Бер сүзем юк бу җиргә,
Мин риза, бәхил, колак сал
Минем соңгы гозергә.

Мин башка гозерләр белән
Сине бүтән йөдәтмәм,
Язмышым, үзең аердың,
Юк әткәм һәм юк әнкәм,
Юк җирдә башка шатлыгым,
Әйтче, мин кемнән, йә, ким?
Әнкәмнән мәхрүм итсәң дә,
Телемнән итмә ятим.

*С.Хәким*

Татарлар Русиядә, кыргызлар һәм казахлар кебек үк, ике теллегә әверелделәр. Урыс телендәге татар мәдәнияте — Израильдә урыс телле яһүд (еврей) мәдәнияте кебек үк бер феномен. Шуның белән бергә балаларыбыз бик тырышып инглиз телен үзләштерә. Өч теллелек — татарларның конкуренциягә сәләтлелек рәвеше. Озакламый тагын бер гамәли бурыч килеп туачак — сәүдә базарларында эшләү, Азиядә эшмәкәрлек җәелдерү. Һәркайда үз урыныңны табу зарур. Революциягә кадәр дә төрки дөньяны тирән белергә кирәк булса, хәзер дә иң таныш һәм иң якын буларак, нәкъ менә шул дөньяны үзләштерү мәҗбүрләшә. Ана телләрен өйрәнсәләр, татарлар төрки дөньяның барлык диалектлары, сөйләмнәре һәм сөйләшләре белән җиңел генә таныша алалар. Безнең дәреслекләрне, төрле төрки халыкларның мәдәниятләрен өйрәнү күзлегеннән чыгып, яңадан карап чыгу мәгъкуль. Татарлар еш кына үзләренә генә хас үзенчәлекләрен купайтып күрсәтергә омтылалар, инде бердәмлегебезгә, охшашлыгыбызга игътибар итәргә вакыт җитте.

Бер генә төрки тел дә хәзерге заман процесслары басымына берьялгызы гына чыдамаячак. Русия һәм Төркия ише зур илләр глобальләштерү афәтен тиз генә аңламаячак әле, аларны территорияләренең зурлыгы, халкының күплеге һәм мәдәният институтларының куәтлеге юата һәм йоклата. Дистәләгән телевидение каналлары тәүлекләр буена урысча яисә төрекчә сөйләп торганда, сәясәтчеләрнең дә, галимнәрнең дә җаны тыныч. Әмма үз мәдәниятен яклап калырлык көч-кодрәте булмаган азрак санлы халыклар үз киләчәге өчен борчылмый булдыра алмый.

Төрки халыклар тарих үзе бүләк иткән үзенчәлекләрдән файдаланырга тиеш: сөйләмнәрнең һәм диалектларның охшашлыгыннан, алар арасындагы киртәләрнең ясалма рәвештә, ягъни дәүләти һәм административ чикләр, алфавитларның төрлелеге һәм шовинистик идеология белән тудырылуын истә тотарга кирәк, ә шовинистик идеологиянең теләсә кайсы һәм теләсә нинди багланышны «пантюркизм» дип атавы көн кебек ачык. Столыпинның махсус хезмәтләр алдына куйган бурычы төрки сөйләмнәрне бер-береннән ерагайтып, бөтенләй яңа мөстәкыйль халыклар булдырудан гыйбарәт булган һәм бу бурычка, кызганыч ки, шактый сизелерлек дәрәҗәдә ирешелгән дә инде. Үзебезнең дә гаебебез җитәрлек: галимнәр озак еллар эзләгән диалект үзенчәлекләре белән танышсаң, хәйран каласың. Нәтиҗәдә, ялган галимнәр уйлап тапкан ялган диалектлар саны иксез-чиксез. Халык үзе күптин-күп «диалектларда» сөйләшүен сизми дә, белми дә, кеше белән кеше аралашканда авазларның һәм сүзләрнең дөрес әйтелешенә әллә ни игътибар да бирми.

Революциягә кадәр фәнни даирәләрдә «төрки-татар сөйләме» дигән төшенчә кулланылган, монда охшаш телләрнең олы бер төркеме күз алдында тотылган. Татар теле күп гасырлар буена күп кенә халыкларның рухи байлыгы булып саналган. Тарих борылышлары бу төшенчәне бары тик Идел буе татарларына гына бәйләгән. Теория ягын онытып, гамәли күзаллаулардан гына чыгып эш итсәң, аерымлыкларга игътибар итмичә, охшашлыкларны эзли башласаң, бүгенге төрки телләр һәм мәдәниятләр төп билгеләре буенча үзара тәңгәлләр. Димәк, гомуми мәгълүмати һәм мәдәни киңлекләр булдыру өмете сүнмәгән әле. Башкортлар башкорт булып калсын, сөйләмнәрен дә башкорт теле дип атасын, кумыклар — кумык теле дип, балкарлар балкар теле дип атасын. Эш анда түгел бит, берләшмичә, ялгызы гына бу халыкларның берсе дә конкуренциягә чыдамаячак. Уртак мәгълүмати метапространство булырга тиеш, иң мөһиме — сөйләмдәге аерымлыкны этникара багланышлардагы үтеп чыкмаслык киртәгә әверелдермәскә кирәк.

Үз дәүләтчелеге булмаган теләсә кайсы аз санлы халыкның бер проблемасы бар — тел һәм мәдәниятне саклап калу һәм бер үк вакытта заманча милләт була алу. «Резервация» юлы да бар, ягъни этниклыкны саклап калу хакына мәдәниятне бикләп кую, башкача әйткәндә, прогресстан үзең теләп баш тарту. Әмма төрки халыкларның үзлегеннән үсәрлек көч-куәте бар. Глобальләштерүдән саклану юлы үзенчәлекләр, тел һәм мәдәният «резервация»сенә бикләнеп калуда түгел. Мәгънә башкада шул — төрки мәгълүмат метапространствосын кору өчен заманча технологияләрдән төрки халыклар мәдәниятләре үсешенә яңа этәргечләр туарлык дәрәҗәдә файдалану зарур, һәм бу юлдагы беренче адым — инглиз алфавитына мөмкин кадәр якынайтылган латин алфавиты нигезендә барлык төркиләр өчен уртак интернет теле уйлап табу.

Төркиләрнең гарәп алфавитына күчүләре ислам дине кабул итүгә бәйле, башкача әйткәндә, аның нигезендә идеология ята, рун язулары төрки тел үзенчәлекләренә бик туры килгән бит. Кайбер халыклар (әрмәннәр, грузиннар, яһүдләр, индуслар һәм башкалар), бөтендөнья үрнәкләренә күчмичә генә, үз милли алфавитларын саклап калганнар. Милләтләрнең кушылу теориясен уйлап тапкан коммунистлар режимы кириллицаны көчләп таккан бит. Бүген бөтен дөнья латинга күчә һәм монда бернинди дә идеология юк, бу — уңайлылык җәһәтеннән чыгып ясалган прагматик адым. Бу процесслардан читтә калу — тарих арбасыннан төшеп калу дигән сүз, шул ук вакытта үз мәдәниятеңнең үзенчәлекләреннән мәхрүм булу куркынычы да яный, ә бу исә юкка чыгуга тиң. Үзенчәлекле татар хәрефләре булган латин алфавитына күчүне әзерләүче авторлар тәкъдим иткән компромисс исә интернет аша аралашуны чикли. Әгәр клавиатураны һәм программаларны билгеле бер алфавитка яраклаштырырга кирәк икән, моны артык эшкә санап, аннан файдаланучылар саны кимеячәк, «цифр упкыны» барлыкка киләчәк, ягъни интернетка керә алучылар белән интернетка керә алмаучылар арасында зур аерма туачак, ә бу исә җәмгыять үсешенә тискәре йогынты ясаячак — артта калганнар тагын да арткарак калачак, ә алдагылар һәм байлар алга китәчәк. Мондый шартларда алфавит аралашу телен сайлауга тәэсир итүче факторга әверелә.

Алфавит әзерләгәндә техник чараларны исәпкә алу зарур. Борын заманнарда язмаларны саклап калу технологиясе хәрефләрнең язылышына үз өлешен шактый керткән. Биредә чөйсыман язу һәм рун алфавитын искә төшерү дә җитә. Мәгълүмат саклаучы материал үзенчәлекле графика таләп итә. Бүген интернет дәвере һәм мәгълүматның электрон саклагычлары алфавитка махсус таләпләр куялар.

Стандарт инглиз клавиатурасы нигезендә төрки халыклар өчен метаалфавит әзерләү «мәгълүмат упкынын» кичерәйтү, уртак милли ресурсларны саклаган хәлдә аларның мөмкинлеген күп тапкырлар киңәйтерлек мәгълүмат киңлеге ясау коралы булырга да мөмкин.

Мондый метаалфавит хезмәтен бер төркем галимнәр тәкъдим иткән «Jnalif» үтәргә мөмкин. Аның асылы төрки телләрнең үзенчәлекле хәрефләрен графемалар һәм символлар комбинациясе белән алмаштырудан гыйбарәт. Мәсәлән, менә мондый «дублерлар» тәкъдим ителә: **ч** — **ch**, **ш** — **sh**, **гъ** — **gh**, **ң** — **ng**, **х** — **kh**, **ж** — **zh**. **Ә**, **ү**, **ө** хәрефләре шуларга якын хәрефләрнең уң ягына апостроф кую юлы белән нечкәртү вазифасын үтәргә мөмкин: **а,, и,, о,**.

Тәкъдим ителгән алфавит шактый сәбәпләр аркасында уңайлы. Ул инглиз хәрефле теләсә нинди стандарт клавиатурага яраклы, шул сәбәпле интернеттан файдаланучыларга бернинди дә өстәмә кыенлыклар

тудырмый. Махсус программалар куюны таләп итми. Өстәмә авазларны беркетү өчен тәкъдим ителгән хәрефләр комбинациясен махсус өйрәтергә кирәкми. «Jnalif» рәсми алфавитка җиңел күчерелә, чөнки компьютер аны шул килеш тә аңлый. Ниһаять, ул барлык төрки телләргә дә яраклы, ягъни ул бу яктан гаять җайлы.

Билгеле ки, алфавит гомумтөрки мәгълүмат метапространствосын булдыру юлында беренче адым гына, әмма ул татарларның, шулай ук үзара кардәш халыкларның аралашуын да җиңеләйтәчәк. Ә киләчәк адымнарны тормыш үзе күрсәтер.

## Дала цивилизациясе

*Тәңредәй күкләрдә яратылган зирәк төрки каган булып бу вакытта тәхеткә утырдым. Сүземне тәгәл ишетегез: барыгыз — кече туганнарым, улларым, бирердәге оям халкы. Көньякка — шад — апыт бәкләр. Төньякка — таркат — боерык бәкләр, утызау, тугыз угыз бәкләре халкы! Бу сүземне яхшы ишет, ныклап тыңла. Алга — кояш чыгышына, уңга — көн уртасына, артка — көн батышына, сулга — төн уртасына кадәр сузылган җирдә яшәүче халыкны тупладым, күбәйттем.*

Йолыгтәгин. Күлтәгин истәлеге
Кече язма, 732 ел

Безнең эрага кадәр 214 елда Цинь ыруыннан Ши-Хунанти атлы күренекле дәүләт эшлеклесе Бөек Кытай диварын төзегән. Ул һуннардан сакланган. Кытай императорлары өчен төньяктагы күчмә халыклар һәрвакыт авыртмас башка тимер тарак булганнар.

Фәнни мәдәнияттә һуннарның этник чыгышы турында күптәннән бәхәс бара. Ирина Засецкая болай дип яза: «Һуннар төрки телдә сөйләшкәннәрме — бу бәхәсле мәсьәлә, әмма һуннар белән Европага төрки дөнья вәкилләре үтеп кергән, бусы — бәхәссез. Күп кенә тикшеренүчеләр билгеләп үткәнчә, һуннарның яу булып керүе төрки халыклар өчен Көнбатышка юл ачкан». Башка җирләрдән булган күзәтүчеләр II — V гасырларда Көнчыгыш Казахстанда яшәгән һуннар дәүләтендәге халыкларның теле гаогюй кабиләләре, уйгурларның борынгы бабалары теленә охшаш дип санаганнар, ягъни төрки телләргә керткәннәр.

Төрки халыкларның килеп чыгышы турындагы риваятьләрдә Ана бүре һәм һуннар шаһзадәсе чагылыш тапкан. Көнбатыш һуннары, имеш, кырып бетерелгән һәм ун яшьлек бер ир бала гына калган, дошманнар аның кул-аякларын кисеп ташлаганнар, ә үзен сазга тотып атканнар. Аны ач үлемнән Ана бүре коткарып калган һәм тора-бара аңа хатын булган. Ир баланы барыбер үтергәннәр, ә Ана бүре Алтай тауларына качкан һәм анда ун ир бала тапкан, шулардан төрки халыклар тарихы башланган. Шушы риваятьтән күренгәнчә, төркиләр көнбатыш һуннардан килеп чыкканнар. Башка риваятьләрдә дә Ана бүре һәм төрки телдә сөйләшүче кабиләләр күренеп-күренеп китә.

Садри Максуди, күп кенә чыганакларны анализлап, һуннарны саф төркиләр дип санаган. Лев Гумилев та шул ук фикердә булган. Сергей Кляшторный, Кытай илчесенең «төньяк» һуннар теленең гаогюйлар теле белән охшашлыгы турындагы сүзләренә таянып, болай дип раслый: чыганаклар «беренче мәртәбә II — V гасырларда Казахстанда һәм Җунһар илендә булган борынгы дәүләтләрдәге бер халыкның теле тәгаен төрки тел икәнлекне билгеләп үтә. Ышанып расларга була: шул заманнан иксез-чиксез казах далаларында «төньяк» һуннар белән бергә төрки телләр семьялыгына керүче борынгы телдә (телләрдә?) сөйләшкән халык яшәгән». Шушы фикерне раслап, болгарлар (һуннарның берсе), һичшиксез, төркиләр. Мөгаен, һуннарның олы берлегенә төрле телләрдә сөйләшүче кабиләләр кергәндер, бу — табигый хәл һәм котылгысыз күренеш.

Һуннар конфедерациясенең үзендә борынгы төркиләрчә сөйләшүче кабиләләр өстенлек итүе бернинди дә шик тудырмый. Ничек кенә булмасын, төркиләр һуннар традицияләренең дәвамчылары булган. Һуннарның варислары роленә дәгъва кылучылар булса, алар арасында, бәхәссез ки, беренче урында татарлар тора.

Дала культурасы һуннар дәвереннән алдарак барлыкка килгән, аның вәкилләре этник яктан гаять төрле булуга карамастан, ул аерым бер цивилизацияне тәшкил итә. Скифлар, сарматлар, һуннар, төркиләр, хәзәрләр, кыпчаклар, монголлар һәм башкалар — болар бар да бер ташкын. Скифлар һәм башка кабиләләр берлекләре шушы культурага нигез салганнар, ә һуннар, соңыннан төркиләр һәм монгол татарлары аны үзләштереп, үстерә барганнар, әмма скифларны этник һәм тел ягыннан тәңгәлләштерү — бик катлаулы бурыч. Ә һуннар, көнчыгыштагылары да (һуннар, сөнниләр), көнбатыштагылары да (шул ук һуннар үзләре) — төрки-татар цивилизациясенең чишмә башы.

Кытайларны күчмәләрнең «кыргый урдалары» куркыта алмаган, алар бик яхшы оештырылган дәүләт системасына ия булганнар. Кытай императоры (безнең эрага кадәр 174 елда бөек Һуннар империясен төзүче Төүмән (Төмән) улы Баһатурга (Көнбатышның тарихи хроникаларындагыча — Маодунь яисә Модэ)

мондый хат җибәрә: «Хуан-ди һуннарның Бөек шаньюйына саулык-сәламәтлек тели. Лан-чжун Сидуцянь алып килгән хатта болай диелгән: Көнбатыш Чжуки кенәз падишаһлар арасында төзелгән шартнамәне Илу-хэу Наньчыжы киңәше белән рөхсәтсез өзде, алар арасындагы туганлык килешүен бозды һәм Хань Йортын күрше держава алдында уңайсыз хәлдә калдырды. Шартнамәнең бозылуы түбәнгерәк түрәләр арасында булганга күрә, Көнбатыш Чжуки кенәз Көнбатышка, Юечжыга сөрелде һәм ул шушы биләмәне буйсындырды да. Ә хәзер исә, сугышны туктатып, гаскәрләргә ял бирергә һәм атларны көрәйтергә кирәк; чик буйлап урнашкан халык тынычлыкта яшәсен өчен үткәннәрне онытырга да элеккеге шартнамәне расларга кирәк; бала-чага үсә төшсен, ә карт-коры гомерләренең азагында булса да тынычта яшәп калсын, һәр ыру тыныч тормышның рәхәтен күрсен. Мин моны бик хуплыйм: чөнки борын заманның изге падишаһлары да шулай фикер йөрткәннәр. Хань Йорты Һуннар Йрты белән туганлашу турында сөйләшеп килешкән, һәм шуңа күрә дә шаньюйга иксез-чиксез күп бүләкләр җибәрә... Илче әйтүенчә, Шаньюй Көнбатыш сугышын шәхсән үзе җитәкләгән һәм зур кыенлыклар күргән. Сезгә үзем кия торган чигүле кафтан, алтын чәч кабы, алтын йөгерткән билбау һәм билбау өчен алтын йөгерткән мөгезборыннан ясалган аел, 10 кисәк чигешле ефәк тукыма, 30 кисәк кама һәм 40 кисәк кызыл һәм яшел төстәге ефәк тукыма җибәрәм. Боларның барысын да зур түрә аша җибәрәм». Кытай императоры һуннар падишаһының (шаньюйның) Эчке Азиядәге иран телендә сөйләшүче юэчжи халкын җиңүен сискәнеп искә ала. Аларның төп тупланган урыннары хәзерге Кытайның Ганьсу провинциясенең көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан булган, ул җирләрдән Азиягә сәүдә юлы узган, ә хакимият исә хәзерге Монголия, Җунһария, Тянь-Шаньның күп өлешен, шулай ук Тарим бассейнын һәм Хуанхэ елгасының югары агымы буйларын биләгән. Сыма Цянь болай дип яза: «Элек заманнарда (юэчжи) бик куәтле иде һәм соңнәргә түбәнсетеп карыйлар иде». Баһатур, юэчжиларга һөҗүм ясап, аларның ватаннары Көнчыгыш Төркестанны яулап алган, ә аның варисы безнең эрага кадәр 165 елда атасы эшен төгәлләгән һәм шуннан соң юэчжилар Көнбатышка бөек чыгыш башлаганнар.

Баһатур гаять атаклы полководец булган, акылына, зирәклегенә күрә аны шаньюй итеп куйганнар. Аның атасы Төүмән, картаймыш көнендә яшь хатынының ятьмәсенә эләгеп, Баһатурны үтереп, хатынының улын тәхет варисы итеп калдырырга риза булган.

Әмма Баһатур бик уяу һәм кыю булып чыккан, бу галәмәтләр аңа мәгълүм булган һәм ул үзенә каршылык корганнарны җиңеп чыккан. Атасы аның зирәклегенә хәйран калган һәм улын меңбашы итеп билгеләп куйган. Әмма Баһатур атасының хыянәтен гафу итәргә җыенмаган. Һәм ул иң башлап «сызгыра торган укның» яңа төрен уйлап тапкан, мондый укны атып җибәрү башка яугирләр өчен хәбәр булган, алар да шул ук юнәлештә атарга тиеш булганнар. «Шуннан соң Маодунь үзенең атына ук атты. Гаскәрендә атмый калганнарның башларын чабып өзәргә әмер бирде. Аннары Маодунь яраткан хатынына ук атты. Сүзен тыңламаганнарның башларын чабып өзде. Ауда чакта Маодунь угын этисенең атына төбәп җибәрде, аның тирәсендәге берәү дә атмыйча калмады. Шул чакта Маодунь язмыш сәгате сукканын аңлады. Ул атасына угын атып җибәргәч, яугирләрнең берсенең дә кулы калтырамады — Төүмән тәнен уклар тишкәләп бетерде». Баһатурның тәхеткә килүен Сыма Цянь шулай тасвирлый. Аның заманнарында һуннар державасы җирләре Маньчжуриядән алып Уралга һәм Каспийга кадәр, Кытай, Тибет һәм Ираннан алып Саянга, Алтай тауларына һәм төньяктан Енисейның үрге агымы буйларына тикле җәелә. Э.Х.Паркер: «Баһатур дөнья тарихында иң бөек яулап алучыларның берсе булган һәм аны чынлап та Татариянең Ганнибалы дип атарга мөмкин. Гәрчә вакыйгалар Урта диңгезнең бары тик бер почмагына кагылса да һәм сүз тиз генә Африка, Персия яисә Галлиягә кереп чыгу турында гына барса да, Европаның мәгърифәтле кешеләре арасында шул вакыйгаларга яңгыравык исемнәр бирү гадәткә кергән булган, мәсәлән, «дөнья хуҗасы», «җир йөзендәге бөтен халыкны җир күчәренә илтеп җиткерү» һәм башка шундыйлар. Кир һәм Александр, Дарий һәм Ксерос, Цезарь һәм Помпей — һәрберсе кызыклы экскурсияләр ясаган, әмма алар шулай ук киң колачлы булмаган һәм, Азиянең көнчыгыш өлешендәге кампанияләрдән аермалы буларак, кешеләрне бик аз кызыксындырган».

Безнең эрага кадәр V — IV гасырларда һуннарда бер-берсенә никах җепләре белән бәйләнгән дүрт аксөяк нәсел җәмгыятьнең өске катламын тәшкил иткән. Бу сан киләчәктә даими рәвештә очрап торачак.

Илчелек вазифасы белән 922 елда Болгар иленә килгән ибне Фадлан болай дип яза: «Без Болгар патшасыннан бер көнлек юлда булган чакта, ул үз кул астындагы дүрт кенәзен, шулай ук ир туганнарын һәм улларын безне каршы алырга җибәрде». Үзбәк дәверендәге Алтын Урданың дәүләт корылышына бәя биреп, әл-Гомәри болай ди: «Бу солтанның хакимнәре — дүрт олыс әмире, шуларның өлкәне бәкләрбәге, ягъни өлкән әмир (дип атала). Һәр мөһим карар шушы дүрт әмир тарафыннан кабул ителә; әгәр берәрсе булмаса, аның исеме ярлыкларга, ягъни әмерләргә языла: ул анда үзе катнашкан сыман яисә аның урынбасары аның урынын алган булып санала». Дәверләр, ханнар, дәүләтләр алмашыначак, әмма Казан һәм Кырым ханлыкларына кадәр сәясәтне билгеләүче дүрт нәсел калачак. Герберштейн «Московия турындагы язмалар»да болай дип таныклый: «Татар патшалары иң мөһим эшләре турында дүрт ир-ат (viros) белән киңәшәләр».

Алар дүртесе дә карачылар. «Карачылар» сүзе «карамак» сүзеннән килеп чыккан. Алтын Урдадан соңгы барлык ханлыкларда шундый ук төзелмәләр булган. Алар дүрт затлы кенәз нәселеннән гыйбарәт: Ширин, Аргын, Барын һәм Кыпчак. Тора-бара Кыпчак нәселе юкка чыга һәм аның урынына ике яңа нәсел килә — Мангыт һәм Сеҗеут, ә аннан да соңрак Мангыт урынын Мансур нәселе алган. Карачылар арасында «олы карачылар» аерылып торган. Шириннар шундый исем йөрткәннәр. Атаклы урыс фамилиясе Ширинских шул нәселдән чыккан. Идарәнең дүрт бәй системасы Монгол империясенең барлык олысларында да хөкем сөргән.

Дүртле саны гасырдан гасырга күчсә дә, очраклы сан гына булырга мөмкин, бәлки, төрле дәверләрдә бу сан дөньяның дүрт ягын аңлаткандыр, шуңа күрә дүрт төп нәсел билгеләнгәндер. Урхун язмаларында без дөньяның дүрт ягына ишарәне еш очратабыз, ханнарны да киезнең дүрт ягыннан тотып күтәргәннәр.

Һуннар дәүләте башлыгы шушы дүрт кенәз нәселенең иң затлысыннан гына булырга мөмкин. Аны «Тәңре Кот» дип атаганнар һәм ул законнар (торе) чыгарган, үзе үк хөкемдар да булган. Бу вазифа бары тик нәсел буенча гына күчкән. Аннан соң әһәмияте буенча сул һәм уң «зирәк кенәзләр» килгән, алар гадәттә аның уллары яисә якын туганнары булган. Алар империянең көнбатыш һәм көнчыгыш территорияләренә идарә иткәннәр һәм бер үк вакытта гаскәрләрнең уң ягын һәм сул ягын җитәкләгәннәр. Аларның саны һәрвакыт бер үк — 24 булган һәм аларны хан үзе билгеләп куйган, аларга тиешле җирләрне бүлеп биргән. Түбән меңбашларны, йөзбашларны һәм унарлыкларны билгеләп куйган, аларга да халкы белән бергә җирләр бүлеп биргән. Бөтен халык бердәм бер гаскәр булып яшәгән. Һуннарда хәрби стан һәм кенәз торган урын «урда» дип аталган.

Төркиләрнең армиясе һәм монгол татарлары гаскәрләре дә тора-бара шул ук унлык системасы буенча корылган, ягъни меңнәргә, йөзләргә һәм унлыкларга бүленгән. Чыңгыз ханның «Яса»сы буенча «меңлекләр һәм йөзлекләр шундый тәртиптә һәм әзерлектә тотылырга тиеш ки, теләсә кайсы вакытта әмер һәм боерык булуга, кичекмәстән, төн дип тормастан, атларына атланырга тиеш». Армиянең үзәге, сул як канаты (көнчыгыш ягы) һәм уң як канаты (көнбатыш ягы) булган. Чыңгыз хан төркиләр оештырган шушы уңай системадан файдаланган.

Һәр һун яугир саналган. Сыма Цянь алар хакында болай дип яза: «Иркен заманнарда, гадәтенчә көтүкөтү терлек куып, кырларда аучылык белән шөгыльләнәләр, шул рәвешле үзләренә ризык табалар; ахыр чиктә һәрберсе хәрби күнегүләр ясый, аннары яу чабасылары бар. Аларның табигый асыллары шул». Барлык ир-атлар балачактан алып вафатына кадәр үз җитәкчесе булган билгеле бер хәрби бүлекчәгә беркетелә. Рим тарихчысы Аммиан Марцеллин һуннар турында язганда: «Алар сугышка чөй сыман бәреп керәләр, шул ук вакытта коточкыч улау авазлары чыгаралар. Җиңел сөякле һәм хәрәкәтчән яугирләр, бер сугышчан линиягә тезелмичә, төрле якка махсус таралалар, теге яисә бу җирдә һөҗүм итеп, бөтенесен кырып чыгалар. Шулай җилдәй җитез йөргәнгә күрә, аларның теге яисә бу ныгытманы камауларын яисә дошман станын талауларын күзәтеп тору мөмкин дә булмый»,— ди. Һуннарның төп сугыш тактикасы кинәт, көтелмәгән рәвештә һөҗүм итүдән гыйбарәт булган, шуңа күрә дошманнары алардан дер калтырап торган. Башка халыклар борын заманнардан аларның хәрби осталыкларын үзләштерергә омтылганнар. Чжао патшалыгы хакиме Улинь-ван (безнең эрага кадәр 325 —299 еллар), «гореф-гадәтләргә хыянәт итеп, варварлар киеменнән йөри башлаган, җайдак һөнәрен үзләштергән һәм ук-җәядән атарга өйрәнгән». Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк: кытайлар чик буйлап ныгытмалар коруны өстенрәк күргәннәр.

Безгә чыганаклардан мәгълүм чорларда һуннар үсешләренең шактый югары дәрәҗәсенә ирешкән. Аларның үз законнары, үз хөкем системасы булган. Сыма Цянь болай дип язган: «Аларның законнары: үткен корал яисә фут күтәргән кешегә — үлем; урлашкан өчен гаиләсе конфискацияләнә, җиңелчә җинаятьләр өчен битенә очлы корал белән эз салына, ә мөһимрәк җинаятьләр өчен — үлем җәзасы. Хөкем вакыты 10 көннән дә артмый. Бөтен бер дәүләттә тоткыннар саны берничә дистәдән артмый». Мондый җәмгыятьне варварлар җәмгыяте дип атап булмый, ахыр чиктә бу җәмгыятьтә канга-кан үче яисә җинаять өчен акча түләү кебек түбән системадагы җәза бирүләр юк, барлык җәза бирү гамәлләре дәүләт кулында булган.

Тормышның мондый рәвеше төркиләрдә һәм монгол татарларында камилрәк рәвешләрдә кабатлана. Төркиләрдә билгеле бер яшькә җиткән һәм «ир аты» алган теләсә кайсы яшүсмер, чыгышына, нәсел-нәсәбәсенә карамастан, «яугир ир-ат» булып киткән. Чын «ир-ат» үзенең байлыгын үз коралы ярдәмендә тапкан. «Мин унбиш яшемдә кытай ханына яу чаптым. Батырлыгым аркасында... ул дәүләттән алтын-көмеш, бер өркәчле дөяләр, хатыннар алып кайттым!» — диелгән ташка басылган язмаларның берсендә.

Дала культурасының нигезе — ат. Дала кешесе өчен «ат сырты ватан булган». Ат — хәрәкәт итү чарасы да, хәрби берәмлек тә. П.Н.Савицкий Л.Гумилевка язган хатларының берсендә: «Күчмә халыклар үз заманында бөтен дөньяга ыштан һәм ияр бүләк иткәннәр. Бу ике гаять мөһим нәрсәнең нәкъ менә күчмәләр дөньясында уйлап табылуына бернинди дә шик юк. Бу уйлап табулар барлык даһи нәрсәләр кебек үк бик гади дә. Болай диярга дә була: ахыр чиктә күчмә халыклар бөтен дөньяны, безнең планетаның барлык җан

ияләрен ыштанлы иткәннәр һәм үз заманында ияргә атландырганнар». Петербургтагы Дәүләт Эрмитажында һуннарның кием-салымнары, биек көпчәкле арбалары һәм көнкүреш әйберләре саклана. Алар, билгеле инде, бик примитив, ыштаннарының рәвеше дә әллә ни түгел, әмма алар уйлап табылган мизгелендә шундый булганнар бит. Күчмәләрне Рим сугышчысы яисә шотланд итәген кигән килеш күз алдына китерүе дә кыен, бүген алары да уңайлы кием-салым буларак түгел, этнографик мирас буларак кына сакланып калган. Бүген исә бөтен дөнья күчмәләр бүләк иткән кием-салымны өстен күрә.

Дала күчмә цивилизациянең хуҗалыгын, культурасын, әхлагын билгеләгән. Әмма тарих барышына йогынты ясаган тышкы сәбәпләр дә булган. Бөек Даланың рәхимсез дошманы — алга киткән һәм күпьяклы Кытай культурасы. Әлеге культура далачылар культурасы шикелле гади һәм примитив түгел, чөнки утрак халык тормышына җир эшкәртү дә, шәһәр тормышы да, алга киткән фәлсәфә дә, бөтенләй башка әхлакый башлангычлар да, зирәк сәясәт һәм хәйләкәр дипломатлык та кергән.

Һуннар тирәлегендә һәрчак төрле партияләр булган. Кайберәүләр: «Кытай үз куәтенең югары ноктасына менеп җиткән... Без һәрьяклап җиңелдек һәм, мөгаен, без горурлыгыбызны онытырга һәм мәңгелек сугышка кермәскә тиештер. Әгәр без Кытайны олыласак, үз башыбызны саклап калачакбыз. Киресенчә эшләсәк, коточкыч үлем җәзасына дучар булачакбыз. Иң яхшы юл ап-ачык бит»,— дигәннәр. Кытай императоры далачыларны үз ягына аудару өчен кыйммәтле бүләкләрен кызганмаган.

Һуннар, хәтта кытай ханнары кызларына өйләнеп, император тәхетенә менеп, үз династияләренә нигез салып, беркадәр вакыт Төньяк Кытайда хакимлек иткәндә дә төркиләр кебек түгел, ә кытайлар кебек идарә иткәннәр. Алар кытай көнкүрешен, әхлагын, титулатурасын һәм йолаларын үз иткәннәр. «Алтынчы йөз дәвамында,— дип яза Э.Х.Паркер,— сиенпи (сянь бийчы) татар династияләре Төньяк Кытайда хакимлек иткәндә Фен елгасы һәм Сары Елга арасындагы Лю Юань биләмәләре чикләрендә яшәүче ярым цивилизацияле татарлар расасы булган... Алар утрак тормышка күчкәннәр, ефәк кузысы үстергәннәр, кытайча укый белсәләр дә, татарча сөйләшкәннәр. Мөгаен, алар ассимиляция процессы кичергәннәрдер, ә аның алшартлары инде салынган булган».

Кытай цивилизациясен өстен күргән һун кабиләләре анда эреп югалганнар, каршы тору идеологиясенә ия булганнары гына сакланып калган. Атаклы юлбашчы Баһатурдан соң аның урынына улы Каяк килгән. Кытай императоры шунда ук үзенең кызын аңа хатын итеп җибәргән, аны хәрәм агасы озата килә. Бу кеше күчмә тормыш яклы булмаса да, үз ихтыярына каршы күчмәләр станында яшәргә мәҗбүр булгач, «Кытай янбашына кадалган шырпы» булырга сүз биргән. Ул күчмәләрнең идеологиясен юлбашчыларга болай дип бәян итә: «Сезнең бөтен урдагыз ике Кытай провинциясе халкы кадәр дә түгел, әмма сезнең көч-куәтегез Кытайдан берничек тә бәйле булмавыгызда. Мин сездәге халыкның Кытай товарларына хирыслыгын сиздем. Кытай байлыгының биштән бер өлеше синең хәтта бөтен халкыңны сатып алырга җитәчәк. Ефәк белән сатин сез җитештергән киезне зәмһәрир салкын көннәрдә берничек тә алмаштыра алмый, ә тиз бозыла торган кытай деликатеслары сезнең кымыз белән сыргa җитәрлекмени?» Хәрәм агасының сүзләре даладагыларның йөрәгенә май булып яткан. Алар: «Безнең табигый көнкүрешебез гайрәтебездән һәм җитезлегебездән гыйбарәт, без кол булып яшәргә өйрәнмәгән һәм эшсез ята белмибез. Атка атланып яу чабу — безнең сәяси көчебез һәм шул ягыбыз белән варвар халыклар алдында өстенлегебезне саклап киләбез. Яуда шәһит китү — һәр яугир өчен дан һәм шөһрәт... Кытай нинди генә көчле булса да, ул безне бөтенләй яулап ала алмый. Кытайны ихтирам итәм дип, нигә без үз йолаларыбызны онытырга, ата-бабаларыбызның рухи хәтерен кимсетергә һәм үзебезне башка халыклар алдында көлкегә калдырырга тиеш?» — дигәннәр.

Һуннар безнең эрага кадәр 51 елда бәйсезлекләрен югалтканнар. Кытайга буйсыну белән барысы да килешкән дип булмый. Көчләр тигезсез булганга, һуннар әкренләп Көнбатышка таба чигенгәннәр. Ниһаять, «тар-мар ителгән һуннар төркеме, мал-мөлкәтләрен һәм хатын-кызларын җуя-җуя, дошманнарыннан качып, Идел-Урал елгалары арасына кадәр барып җиткән». Бу 155 —158 елларда булган хәлләр. Һуннар, җирле халык белән кушылып, 200 елдан соң Рим империясен тетрәткән дәһшәтле һуннарга әверелгәннәр. Күченеп йөрүче һуннар сан ягыннан әллә ни күп булмасалар да, җирле кабиләләргә тарихны хәрәкәтләндерүче көчкә әвереллдерерлек рух өргәннәрдер, мөгаен.

Бөек Дала үзенең бәйсезлеген күчмә мәдәният буларак кына саклап кала алган, киресенчә булган очракларда ул сан ягыннан өстен дәүләтләрдә эреп югалган. Күчмә һәм утрак цивилизацияләрнең үзара каршы тору темасы төркиләр тарихының буеннан-буена берничә мәртәбә кузгатыла һәм күп кенә очракларда сәясәтне дә билгели. Йолыгтәгин ташка болай дип яза: «Алтын, көмеш, исерткеч, ефәкне хисапсыз биргән табгач халкының теле татлы, малы йомшак иде. Татлы теленә, йомшак ефәк малына кызыккан еракта яшәүче халыкны шулай үзенә якынайта иде. Төрки халкы аларга якын яшәп, аларның яман гадәтләрен үзенә сеңдерде». Күлтәгингә багышланган язмаларда «яман гадәтләр» төшенчәсе болай аңлатыла: «Табгач халкы алдаулар һәм котыртулар нәтиҗәсендә һәм кызыктырулар аркасында, шулай ук олыларны кечерәкләр белән талаштыру аркасында халыкны һәм хакимнәрне бер-берсенә каршы куйды,— төркиләрнең иле

таркау хәлдә калды». Бу язмаларда ике дәүләтнең генә түгел, ике идеологиянең каршылыгы чагыла. Төрки каганлыгы хакимнәренең берсе кальгалар һәм монастырьлар төзергә җыенган. Аңа мәшһүр киңәшчесе Төнйокук каршы чыккан, ул үзе табгачларда укып йөргән һәм элеккеге күчмәләрнең Кытайдагы игенчелек цивилизациясе белән танышканнан соң кемнәргә әверелəсен ап-ачык күз алдына китергән: «Юк! Төркиләр аз санлы халык, Кытайның йөздән бер өлешен дә тәшкил итмиләр, безнең аларга каршы торырлык көчебез — үз ризыгыбызны үзебез белән йөртүдә һәм сугыш сәнгатен һәркайсыбызның ныклап өйрәнүендә. Әгәр безнең яу чабарлык хәлебез булса, без яу чабабыз, әгәр инде хәлебездән килмәсә, без качып калабыз, һәм безне бернинди Кытай армиясе дә таба алмаячак. Әгәр без шәһәрләр төзи һәм тормыш рәвешебезне үзгәртә башласак, көннәрнең берендә беребез дә җир йөзендә калмаячак. Монастырьларның һәм храмнарның төп асылы — кешеләрнең холкын йомшартуда, кешелеккә сугышчаннар һәм аяусызлар гына хакимлек итә». Бу чыгышта бөтен күчмә цивилизациянең дөньяга карашы тупланган.

Күчмәләр мәдәнияте күп элементлардан торган шуларның берсе — әхлакый хәзинәләр — тугрылык һәм үзара ярдәмләшү культы. Чыңгыз хан бу сыйфатларны аеруча өстен күргән. Ул кешеләрдә тугрылыкны, бирелгәнлекне һәм чыдамлыкны аеруча хуплаган. Хыянәт, сатылу һәм куркаклык сыйфатларын күралмаган.

Хәрәзм шаһы Мөхәммәт улы Җәләлетдин Чыңгыз ханга каршы бик нык торган, әмма ахырда Чыңгыз хан аны Һинд елгасы ярларына куып китергән һәм исән килеш кулга төшерергә теләгән. Җәләлетдин соңгы мәртәбә бу камаудан ычкынырга тырышып караган һәм, барып чыкмагач, хәрби киемнәрен салып атып, кулына үз байрагын күтәреп, аркасына калканын куеп суга сикергән. Чыңгыз хан елга буена йөгереп килгән, аны куып тотарга омтылган яугирләрен туктаткан да, Җәләлетдингә күрсәтеп, улларына болай дигән: «Мондый улы булган атаны бәхетле дип атап була». Җәләлетдин елганы кичеп чыккан һәм калган яугирләре белән Дәһли тарафына юнәлгән.

Чыңгыз хан бик күп патшаларны тәхетеннән төшергән, һәм һәр җирдә үзләренең хыянәте белән аңа ярдәм итә торган сатлыклар табылып торган. Һәр җиңүеннән соң ул хакимнәренә хыянәтчеләрне үтерергә кушкан. Шул ук вакытта ул ватаннарына һәм хакимнәренә тугры калганнарны үзенә якынайткан. Ул мондый кешеләрнең үз намусын һәм абруен матди байлыклардан, шәхси иминлектән өстен куюларын аңлаган. Әгәр алар Чыңгыз ханга хезмәт итәргә риза булмасалар, ул аларны бүләкләп иреккә җибәргән. Бөек илбасарның үз намус кодексы булган. Чыңгыз хан баһадирлары менә дигән рыцарьлар. Алар арасында тәре йөртүче-тамплиерлар кебек сатлыклар булмаган. Шулай итеп, урыс баһадирлары культы әнә шул борын заманнарга барып тоташа.

Дала кешесе бөтен гомерен атка атланып уздырган, бу исә төрки халыкларга гаҗәп хәрәкәтчәнлек һәм җитезлек тәэмин иткән. 200 — 400 елларда ияр-өзәңге уйлап табу яугирләрнең хәрби куәтен икеләтә арттырган, авыр кылычны алыштырган кәкре кылычка көчле селтәнү өчен таяныр урын биргән. 700 метрга кадәр үк ата торган озын төзелмәле җәя-ук күчмәләргә җиңү алып биргән.

Һуннар һәм төркиләр поход тормышы коруның гаять рациональ рәвешләрен уйлап тапканнар. Төркиләрнең рационализмы күзәтүләрдән түгел, тормышның үзеннән килеп чыга. Һәр халыкның фәлсәфи категорияләргә үз юлы бар. Борынгы греклар, ирекле шәһәр-дәүләтләрнең төрлелеге һәм аларда хөкем сөргән демократия нәтиҗәсендә кешелек аңының бөтен нечкәлекләрен үзенә туплаган гаять үзенчәлекле һәм тиңдәшсез фәлсәфә мәктәбе төзегәннәр. Римлылар юллар салу белән һәм империяне ныгытырлык кануннар чыгару белән шөгыльләнгәннәр. Кытай һәм Һиндстанда үз-үзеңне аңлау тирәнлекләренә төшенгәннәр. Төркиләр дөньяга караш проблемаларын мөстәкыйль хәл иткәннәр. Кытай традицияләре белән якыннан таныш булсалар да, кытайларның динен, фәлсәфәсен һәм кануннарын җентекләп өйрәнсәләр дә, аларның көнкүреш һәм җитештерү системасы башка халыкларның яшәү рәвешеннән бик нык аерылып торган. Аларның яңага һәм билгесезгә омтылу хисләре походлар оештыруда һәм дәүләт коруда ачык күренә. Үзенчәлекле фәлсәфәләре исә — кырыс тормыш шартларының чагылышы. Төркиләр төгәллекне яратканнар һәм тормышта рационализмга, прагматизмга өстенлек биргәннәр. Бу яктан алар борынгы киникларга якын. Диоген кебек мичкә эчендә яшәмәсәләр дә, аларның торагы киниклар  көнкүреше гадилегеннән ерак китмәгән.

Төркиләрдә арба торак та, хәрәкәтләнү чарасы да, кальга да булган. Кытайлар III — IV гасырларда уйгурларны юкка гына гаогюй — «биек арба» дип, ә V йөздә — «тэле» (тәгрәк — «арбачылар») дип атамаганнар. Кайвакыт алар шушы арбаларга бәләкәй генә, җиңел генә тирмәләр урнаштырганнар һәм аларга дөяләр, үгезләр җиккәннәр. Э.Дженкинсон сәяхәте вакытында «ерактан шәһәр булып күренгән» меңләгән арба-йортларда йөрүче күчмә нугайларны очратып хәйран калган. Болай оешу байтак халыкка дала буйлап меңнәрчә чакрымнар узарга мөмкинлек биргән.

Тирмә беренче карашка гына бик гади тоела, чынлыкта исә ул архитектура ягыннан гаҗәп камил. Түгәрәк булганга күрә, ул җылыны яхшырак саклаган. Аны еш кына ике гөмбәзле итеп тә эшләгәннәр. Гөмбәз-

ләр арасындагы һава салкыннан һәм эсседән саклаган. Тирмәне хатын-кызлар да бик тиз җыеп куя алган, нәкъ уртасында учак ягып ашарга әзерләгән. Алар арбаларында ук чалыр өчен үзләре белән бәрән-сарык йөрткәннәр. Тирмәләр иркен булган һәм бик яхшы җилләтелгән, чөнки гөмбәз өстендә тәрәзә сыман тишек булган, төтен дә шуннан чыккан, яктылык та шуннан төшкән. Ханнарның тирмәләренә биш йөзләп кунак сыйган.

> *«Бигрәк шәп тирмә килеп чыкты! Эче иркен! Өсте матур! Ишеге дә бигрәк күркәм! Төнлек боҗрасы гаҗәп төгәл! Аны чорнаган баулар да күз явын алырлык!»*
> *«Фал китабы». Х гасыр*

Күчмәләргә бик шикләнеп караучы Рим елъязмачысы Аммиан Марцеллин: «Һуннар ат өстендә йөргәндә үз асларына теләсә нинди мал-туар итен салалар да, искергәч, аны чи килеш ашыйлар»,— дип раслаган. Чынлыкта исә күчмәләр атларын өзәңге җәрәхәтләсә, аларның сыртын шулай дәвалаганнар. Алар атларын бик нык саклаганнар, чөнки бөтен гомерләре атта узган. Марцеллинның бу карашы, татарлар турында ялган фикер тудырып, китаптан китапка күчә килә.

Төркиләрнең күтәрелүе хәрби уңышларга гына түгел, һөнәрчелекнең, мәсәлән, металл җитештерүнең үсүенә дә бәйле. Алар тимер, бакыр, алтын чыгаралар, аларны эретеп, хезмәт кораллары, хәрби кораллар һәм бизәнү әйберләре ясыйлар. Алтай төркиләре VI гасырда хезмәт кораллары һәм хәрби кораллар рәвешендә жу-жаннарга ясак түлиләр. Булачак каган Бумын жу-жан хакиме Анакувайдан кызын хатынлыкка сорагач, тегесе ул заманнарда бик кимсетерлек җавап биргән: «Сез — тимерчеләр генә һәм безнең коллар гына бит». Татарстан территориясендә табылган көмеш бизәнү әйберләре Беренче Төрки каганлык чорына карый һәм аларны бүген дә тагып йөрергә мөмкин — алар бик оста эшләнгән һәм теләсә кайсы хатын-кызны бизи ала.

Дала тормышы үз кануннарын китереп чыгарган. Күчмәләр өчен урман, тау һәм диңгез сокландыргыч нәрсәләр түгел, алар анда гомер итә алмаганнар. Аларның стихиясе — дала, дала — аларның туган җире. Дуслар да, дошманнар да далада гына яши, чөнки күчмә халыклар экспансиясен тотып торырлык бердәнбер фактор көтүлекләр булган һәм көтүлекләр өчен сугыш барган. Куе урманнар каплап алган урыс җирләре күчмәләргә кирәкмәгән, ә урыслар, утрак халык буларак, күчмәләргә зыян китермәгән. Шул ук вакытта дала кешеләре дә, урманныкылар да бер-берсе җитештергән әйберләргә мохтаҗ булганнар, үзенә күрә бер симбиоз барлыкка китереп, үзара сәүдә иткәннәр.

Славяннарның хуҗалыгы урманнарга һәм елга-үзәннәргә нык бәйле булган, бу аларның икътисадын һәм дәүләтчелек рәвешен билгеләгән. «Теге яисә бу елга системасына ия булган һәр халык Евразиянең билгеле бер өлешенә генә ия булган, дала системасын үзләштергән халык исә бөтен Евразиянең хуҗасына әверелгән, чөнки дала буйлап агучы барлык елга системаларына хуҗа булып, һәр елга системасын тулаем үзенә буйсындырган. Шулай итеп, бөтен дала системасына хуҗа булган дәүләт кенә бөтен Евразияне берләштерә алган». Күчмәләрнең бик күп халыкларны зур-зур дәүләтләргә берләштерә алуы нигездә шуның белән аңлатыла.

Күчмәләрнең хәрәкәт итү чарасы дошманнардан саклану чарасына, кешеләрне, терлекләрне һәм азыктөлекне саклап калырлык бәләкәй кальгага бик тиз әверелә алган. Төннәрен мондый йорт-арбалар һәм ике көпчәкле арбалар түгәрәк ясап тезелгәннәр, үзәгендә юлбашчы тирмәсе һәм аның байрагы урнашкан. Бу сугышчан берәмлек тә, хуҗалык берәмлеге дә булган. Хатын-кызлар хуҗалык ягын караганнар, кирәк чакта алар да тору урыннарын яклап сугышканнар, ирләр яу чапканнар, тыныч чорда ауга йөргәннәр, гадәттә, җанварны күмәкләшеп камау юлы белән аулаганнар. Һәр ир-ат коралланып, бер-беренә бәйләнгән берничә ат белән сугышка кергән. Тыныч тормыш бары тик киләчәк сугышка әзерләнү чоры гына булган.

Тынычлык һәм сугыш чорларының тәңгәллеге һуннарга, төркиләргә, кыпчакларга, монгол татарларына ике меңьеллык буена җиңү китергән. Монгол империясендә шәһәрләр төзелә башлауга ук, дала культурасы бөтен дөньяда тоткан ролен җуя башлаган. Күчмә культураның иң бөек казанышы — Алтын Урда һәм ул бер үк вакытта аның тарихи азагын да аңлата. Бу культураның атрибутлары алтын чатырлар, лачын белән ауга чыгу һәм ат культы рәвешендә калган әле, ә культура үзе Көнчыгыш Европа, Идел буе һәм Урал буйларының шәһәр урамнарында эреп югалган. Күчмә цивилизация хакимлекнең иң югары биеклекләренә ирешкән мизгелендә үзе дә сизмәстән бетүгә йөз тоткан.

Русия казаклары (калмыкларны, нугайбәкләрне һәм башкаларны да кертеп) дала традицияләре варислары булганнар — тормышны җайга салу рәвешләре һәм аның конкрет төрләре — барысы да күчмәләрдән алынган. XVI гасырның беренче яртысында Бистә Украинасына (хәзерге Харьков өлкәсе, Донецк өлкәсенең бер өлеше, Луганск, Сумск, Воронеж, Белгород һәм Курск өлкәләре территориясенә) украин казаклары һәм Польшадан качкан крестьяннар килеп утыра башлаган. Донда казаклар 1549 — 1551 елларда барлык-

ка килгән. Аларның этник составы гаять чуар. Урыс илчеләре язганча, Донда «урыс кешеләре генә түгел, татарлар да, чиркәсләр дә, литвалылар да яши; күп өлеше казаклар гына түгел, ә чиркәсләр, литвалылар һәм татарлар». Аларга Сары Азман җитәкчелек иткән. Казаклар арасында нугайларның Донга күчүләре турында риваятьләр яшәп килә. Нугай кенәзе Иштирәк, Кума буйларында күчмә тормыш белән яшәгәндә, Дон елгасы ярындагы шифалы чыганакларда авыру кызын дәваларга уйлаган. Кенәз кызын казаклар атаманы Сары Азман күреп алган һәм гашыйк булган. Төннәрнең берендә кыз аның янына качып киткән. Иштирәк аны куа чыккан, әмма атыннан егылып төшеп һәлак булган. Нугайларның күбесе бу хәлләрдән соң Сары Азман ягына чыкканнар һәм аның ирекле казакларына әверелгәннәр.

1625 елның 22 октябрендә казаклар мөстәкыйль хәрби-административ структура буларак Русия составына кертелгән. Бистә казакларының төп хәрби оешмасы йөзлекләргә һәм куреньнарга бүленүче полктан гыйбарәт. Көньяк чикләрне саклаганга күрә, казакларга җир бүлеп биргәннәр һәм салымнардан азат иткәннәр. Казаклар бу эшне, заманында һуннар Кытайда император хезмәтендә торып, Бөек Кытай диварыннан төньяктарак чик сакчылары бурычын үтәгән шикелле үк башкарганнар.

Шулай итеп, гаҗәеп бер әверелеш килеп чыккан: дала культурасы утрак игенчеләргә күчкән һәм шунда ныклап тамыр җәйгән. Урыслар Далада яшәргә керешкәч, үзләрен күчмәләрдәй тота башлаганнар, әмма күченеп йөргәннәр. Алар балык тотканнар, җир сөргәннәр, әмма терлекчелек белән шөгыльләнмәгәннәр. Урыс субэтносы буларак, казакларның статусы гаять каршылыклы.

Казаклар бөтен дөньяга хәрбиләр буларак танылганнар, бигрәк тә Парижга кергәннән соң. Әмма XX гасырда мондый тормыш рәвешенең кирәге калмый. Гражданнар сугышында Нестор Махно, тачанка уйлап табып,  дала сугышлары тактикасын камилләштерә алган, шуның нәтиҗәсендә атлы гаскәрләрнең куәте арткан, әмма тарихи күзлектән караганда, бу аларның соңгы көннәре булган. Гражданнар сугышы елларында казакларны юк итү фаҗигагә әверелгән — алар җәмгыятьтә сыйнфый бүленешнең марксистик төшенчәләренә сыймый калалар, чөнки алар буржуйлар да, пролетарийлар да, крестьяннар да түгел, моннан тыш әзер иррегуляр армия бик әйбәтләп өйрәтелгән һәм шуның өстенә шәпләп коралландырылган, аммуниция һәм атлар белән тәэмин ителгән. Репрессияләр һәм эмиграция казаклар тормышын тамырдан корыткан. Икенче бөтендөнья сугышында төп җиңүне танклар тәэмин иткәнгә күрә, Буденный да үзенең атлы гаскәре белән көлке бер хәлгә калган.

Хрущев, Казахстанның чирәм җирләрен аркылыга-буйга сөрдертеп, дала кешеләренең элеккеге СССР территориясендәге соңгы сыену урыннарын юк итте. Бүген күчмәләр культурасының бәләкәй утраучыклары Монголиядә һәм тагын берничә илдә генә сакланып калган, әмма алар экзотика рәвешендә генә яшиләр һәм бүгенге тарихи процессларга берничек тә йогынты ясый алмыйлар. Дала культурасы, бөтен дөньяны ыштанлы, өзәңгеле, иярле итеп, атларга һәм сәяхәтләргә хирыслык, авыр походларда бер-береңә ярдәмләшү, җыйнак һәм җиңел палатка сыйфатында тирмә калдырып, тормышның башка рәвешләре арасында эреп югалды.

Татар культурасында Дала цивилизациясеннән бары тик иксез-чиксез киңлекләрдә генә барлыкка килә алган озын, моңлы көйләр һәм тел структурасында чагылыш тапкан фикерләү рәвеше сакланып калган. Төркиләр психологиясен характерлап, кенәз Н.С.Трубецкой болай дип язган: «Төркиләрнең фантазиясе ярлы да, кыюсыз да түгел, аның колачы киң, әмма ул колач рудиментар: күзаллау көче детальләп эшкәртүгә дә, төрледән-төрле нечкәлекләрнең җыелмасына да түгел, ә кем әйтмешли, аркылыга-буйга үсешкә юнәлгән; шушы күзаллаулар сурәте төрле төсләр һәм төсмерләр белән чуарланмаган, ул пумаланы иркен, кайвакыт искиткеч иркен селтәп төп төсләр белән ясалган. Бу киңлеккә омтылыш төркиләр иҗатына аеруча хас һәм шул ук төрки психиканың төп үзенчәлекләреннән килеп чыга... Төркиләр симметрия, ачыклык һәм тотрыклылык ярата һәм боларның барысы да үзеннән-үзе бирелгән булырга тиеш, инерция буенча аның фикерләрен, гамәлләрен һәм тормыш рәвешен билгеләргә тиеш: тормышын һәм тормышка карашын корырлык төп схемаларны һәм чыганакларны эзләп тору төркиләр өчен кыен, чөнки болай эзләнү һәрвакыт тотрыксызлык һәм төгәлсезлек хисенә бәйле. Шуңа күрә дә төркиләр һәрчак чит-ятларның әзер схемаларын теләп үзләштергәннәр, ят җирләрнең диннәрен кабул иткәннәр. Әлбәттә, төркиләр үзләренә дөньяга карашның теләсә нинди рәвешен алмаганнар. Төркиләр өчен дөньяны танып белү рәвешендә ачыклык, гадилек һәм, иң мөһиме, бөтен нечкәлекләре белән бар дөнья сыярлык уңайлы схема булырга тиеш». Дөньяны болай танып белү рәвеше Дала цивилизациясеннән килә. Билгеле, шәһәр культурасы һәм бигрәк тә ислам хәзерге заман төркиләренә йогынты ясамый калмый, әмма борын заманнарда барлыкка килгән беренчел төшенчәләр һәм психика төрки-татар цивилизациясенең нигезен тәшкил итә.

«Күчмәләр — кыргый халык» дигән ясалма фикер яшәп килә. Гадәти фикерләү ике кырлы принципка корылган: күк йөзе — җир, фәрештә — шайтан, цивилизация — варварлык. Күчмә культураны цивилизациянең капма-каршысы дип кабул итү дә шул принциптан килеп чыга. Чынлыкта исә күчмә культура варварлык түгел, ул — цивилизациянең аерым бер төре. Билгеле, ул игенчелектән һәм шәһәр тормышыннан

нигезеннән үк аерылып тора, чөнки үзенчәлекле тормыш шартларыннан килеп чыга, әмма Көнбатыш цивилизациясе, нигездә, кытай, фарсы һәм башка культураларны үзләштерә алмаган кебек үк, Бөек Даланы да үзләштерә алмый. Моны күчмә цивилизация генә башкара алган. Аның тарихи әһәмияте дә нәкъ менә шунда. Әмма күчмә культураның күп кенә төшенчәләре — европалылар өчен чит нәрсәләр. Аммиан Марцеллин һуннарны бик кимсетеп язган: «Аларның берсе дә кайда туганын белми: бер җирдә ясалган, икенче бер урында туган, өченче бер җирдә үскән». «Күчмәләрдә ватан хисе булмаган» дигән фикер яши. Бу бер дә дөрес нәрсә түгел, чөнки аларның ватаны — бөтен Дала. Фарсы падишаһы Дарий скифларны буйсындырырга омтылган, тегеләре исә сугышка кереп тормыйча гына ил эченә чигенә башлаган. Геродот сүзләре буенча, Дарий скифлар патшасына чапкын җибәргән: «Ник син һаман качып йөрисең? Сиңа бит сайлау мөмкинлеге бирелгән»,— дип сораткан һәм мондый җавап алган: «Падишаһ, минем халәтем шундый! Мин элек тә беркемнән дә курыкмый идем, хәзер дә синнән качуым түгел. Тыныч заманнарда нишләсәм, хәзер дә шуны эшлим. Ни өчен шул ук мизгелдә синең белән сугышка кермәдемме — монысын да аңлатып бирә алам. Безнең бит шәһәрләребез дә, эшкәртелгән җирләребез дә юк. Без аларны җимерерләр дип куркып тормыйбыз, шуңа да әлегә сугыштан баш тарттык. Әгәр дә кичекмәстән безнең белән сугышка керәсегез килә икән, безнең ата-бабаларыбызның каберләрен табыгыз да җимерергә тырышып карагыз, шунда белерсез: без ул каберләр өчен сугышырбызмы, юкмы?» Күчмәләрнең ватан хисе бүтәнчә, ул яхшырак та, начаррак түгел, ул — бүтән. Үз көтүлекләренә яисә ата-бабалары зиратларына һөҗүм ясамаган кешеләр алар өчен дошман түгел, алар юкка-барга сугышып йөрүне мәгънәсезлек дип санаганнар.

Нугай Урдасы кешеләре өчен «ватан» төшенчәсе «яйлау — кышлау йире» сүз тезмәсе булган, ягъни бу аларның күчеп йөрү территориясе. Аны бүгенге мәгънәдәге дәүләт чиге дип атап булмый, шулай да бу алар өчен генә билгеле көтүлекләр, билгеле, шул көтүлекләргә кызыккан кешеләр җәзасыз калмаганнар.

Татарлар утрак тормышта яши башлагач, шәһәрләр коргач, «ватан» төшенчәсе үзгәргән. «Идегәй» дастанында мондый юллар бар:

И Идел-йорт, Идел-йорт,
Идел эче имин йорт,
Атам кияү булган йорт —
Иелеп тәзем кылган йорт;
Анам килен булган йорт —
Иелеп сәлам әйткән йорт;
Кендегемне кискән йорт,
Керем-коңым юган йорт;
Бия сауган сөтле йорт,
Кымыз эчкән котлы йорт;

Идел—Җаек арасы —
Елкы белән тулган йорт,
Казан — Болгар арасы —
Кала белән тулган йорт;
Ашлы белән Ибраһим —
Ашлык белән тулган йорт,
Ата-бабам откан йорт,
Котлы булсын туган йорт!

Алтын Урда дәверендә «туган ил» төшенчәсе бөтенләй башка мәгънәгә ия була. Бу — Идел, шулай ук Җаек, Нократ, Чулман елгалары, бу — иген басулары һәм көтүлекләр. Бу — иксез-чиксез дала һәм яшел хәтфә болыннар, бу — шәһәрләр, барысы да халыкның таянычы, халыкның яклаучысы. Туган ил хисе әверелеш кичергән, чөнки хуҗалык итү культурасы һәм характеры үзгәргән.

Казан ханлыгы җимерелгәннән соң татарларның гомере урманнарда, аерым авылларда узган, һәм туган ил кинәт кенә кечерәеп калган. Җыен (язгы бәйрәм) узган җир туган илгә әверелгән, чөнки анда алар берберсен күргән, очрашкан, тауар алмашкан, җырлаган-биегән. Язгы чәчүгә бәйле рәвештә һәр авылда узучы сабантуй түгел, ә нәкъ менә җыен күп авылларны берләштергән. Бу тирәлектән читтәге һәрнәрсә тормышка яный дип саналган һәм шулай булган да. «Кара урман» җыры нәкъ менә шул хисләргә багышланган. «Кара да гына урман» туган ил чикләренең бер образына әверелгән.

Кара да гына урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә;
Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк дөнья көтәргә.

Татарлар, бер-берсе белән очрашкач, гадәттә «Син кайсы яктан?» дип сорыйлар. Мин «Казан артыннан» дип җаваплыйм. Бу — ата-бабаларымның аралашу тирәлеге, ул «туган ил» төшенчәсе сыйфатында хәтергә уелып калган. Андагы сөйләм яисә культура башка төбәкләрдән аерылып тора дип тә әйтеп булмый, әмма бу — горурланырлык нәрсә: Курсави да, Мәрҗани дә, Тукай белән Галиәсгар Камал да, башка мәгълүм шәхесләр дә Казан арты төбәгеннән чыккан, татар культурасының байтак өлеше нәкъ менә шунда формалашкан.

Швейцариядә һәркем үзен бәләкәй бер территория — коммуна гражданы дип саный, башка урында яшәсә дә, ата-бабалары чыккан коммуна бюргеры (гражданы) булу белән горурлана. Ул гына да түгел, чит ил кешесенә Швейцария гражданлыгы бирер өчен башта федераль органнарның рөхсәтен алырга кирәк, аннары кантон парламентында тавыш бирү уздырылырга тиеш, ә гражданлык аңа нәкъ менә коммунада бирелә. Бу коммунада мең генә кеше торырга мөмкин (хәтта ун кешелесе дә бар), ләкин нәтиҗәдә Швейцария гражданлыгын бирүне коммуна хәл итә. Швейцария коммуна, кантон һәм бөтен баскычларында катлаулы тәңгәллек системасы булган гаҗәп бер җәмгыять корган. Әлегә кадәр бу система Америка системасына каршы бер гаҗәеп күренеш сыйфатында кабул ителә иде, әмма тәҗрибәдән күренгәнчә, кешелек дөньясы, күп тәңгәллекләр парадигмасын кабул итеп, бәлки, нәкъ менә шул юлдан китәр дә инде. Беренче карашка төрле дәрәҗәдәге гражданлык халәте аралашуга һәм хәрәкәтчәнлеккә комачаулый, әмма коммуна һәм кантон гражданлыгында община элементы бар, бу нәзакәтле индивидуальлеккә каршы тора.

Бүген татарлар өчен «туган ил» төшенчәсе киңәйде, һәм аңа Казан арты, Кама буе һ.б.лар кебек ниндидер тирәлек кенә түгел, бөтен бер Татарстан Республикасы керә, ә бүтән татарлар өчен — Идел буе, Урал, Себер яклары. Ә чит илдә без үзебезне Русиядән дип атыйбыз. Күп тәңгәллелек элеккеге «туган ил» төшенчәсен берьяклы аңлауны алмаштырды.

Еллар узар, һәм татарлар үзләрен европалылар яисә бөтендөнья гражданнары дип атарлар — нәкъ Чыңгыз хан заманындагы сыман. Икътисад, культура, аралашу чаралары үсешенең хәзерге заман тенденцияләрен һәм кешеләрнең яшәү рәвешенә әйләнеп баручы хәрәкәтчәнлеген исәпкә алсаң, мондый әверелеш бөтенләй фантастика булып тоелмый. Күчмә культура күләгәсе һич көтмәгәндә XXI гасырның иң заманча җәмгыятьләрендә менә шулай чагылып-чагылып ала.

## «Мәңгелек Күк Тәңре»

*Өстә — Күк Тәңре, аста көрән җир яратылганда, ике арада кеше углы барлыкка килде. Кеше угыллары өстеннән борынгы бабаларыбыз Бумын каган, Истәми каган идарә иткән. Тәхеттә утырып, төрки халыкның илен һәм кануннарын саклаганнар, үстергәннәр. Дүрт ягында дошман күп булган, сугышып, дүрт ягындагы халыкны буйсындырганнар: башлының башын идергәннәр, тезлене тезләндергәннәр. Элгәре көнчыгышка, Кадыркан ешлыгына (Зур Хинган тауларына) кадәр, кире көнбатышка, Тимер Капкага кадәр төрки халыкларны урнаштырганнар. Ике арадагы иясез Күк төрекләрне җитәкләде, алар тәхеткә утырдылар. Каганы белемле, зирәк икән, алып (көчле) каган икән, идарә итүчеләре шулай ук зирәк икән, батыр икән, бәкләре һәм халкы шулай ук төз (тугрылыклы) икән. Аның өчен илне шулай тотканнар, илне тотып, аның кануннарын үтәгәннәр.*

Күлтәгин истәлеге. Олы язма. 735

IV гасырда Урал итәкләреннән көнбатышка юнәлгән һуннар халыкларның бөек күченешен китереп чыгарганнар. Алар тотрыклы тигезләнешне җимергәннәр, һәм кабиләләр, халыклар, дәүләтләр күчүе башланып киткән. Һуннар белән Рим папасы да, фарсылар да, Византия дә юмакайлана. Рим империясе, Аттила һөҗүменә чыдый алмыйча, ике өлешкә таркала. Һуннар мәйданнан китәргә дә өлгерми, шул ук тарихи вакыйгалар театрында төркиләр пәйда була, һәм Аттила державасыннан да зуррак һәм куәтлерәк яңа империя төзелә. Ашин каган ыруы исеме белән күп кенә төрки дәүләтләр барлыкка килә, Дунайдагы Икенче Болгар патшалыгы — Асеней династиясе — Дунай кыпчакларыннан (Ашиннан) килеп чыккан. Аннары Бөек Дала Дәшти Кыпчакны дөньяга китерә. Һәм, ниһаять, Чыңгыз хан пәйда була һәм бөтен Евразияне тетрәтә. Азиядә ашиннар ыруы урынына чыңгызлар өстенлек ала.

Аттиланы, бөек каганнарны, Чыңгыз ханны җиңүләрдән җиңүләргә нәрсә этәрә? Бөтен Азия аша Европага барып чыгу — безнең ата-бабаларыбызның нинди тарихи вазифасы ул? Нәрсә кирәк булган аларга?

Бу феноменны кемгәдер бәйләп тә яисә матди ихтыяҗларга, көтүлекләр һәм җирләр җитмәүгә, икътисадка һәм сәясәткә бәйләп тә — һичничек тә аңлатып булмый. Кеше өчен хыял булганнарның барысына да ирешкән саен, алар тагын да түргәрәк узганнар, көндәлек тормышның рәхәтеннән ваз кичеп яу чапканнар һәм иксез-чиксез җирләрен тагын да киңрәк итү өчен гомерләрен дә кызганмаганнар. Чыңгыз хан даос мо-

нахы Чан-чунга: «Бар минем бер кулмәгем, бер ашамлыгым бар, мин сыер һәм ат көтүчеләр кигәнне киям, алар ашаганны ашыйм», — ди. Нәрсә эзләгән икән соң ул?

Чыңгыз хан рухы гомер-гомергә кешелек дөньясы хәтерендә саклана, әмма монгол татарлары өчен ул галәми колачтагы шәхескә әверелгән. Искәндәр Зөлкарнәен дә (Александр Македонский), Наполеон да чыңгызлар гамәлгә ашырган мәшһүр проектларга хәтта якыная да алмаган. Җир шарын үзгәртеп коруда Чыңгыз хан роле бөек диннәргә тиңдәш. Рәшидетдин сүзләренә караганда, «Чыңгыз ханның Тәңренең яраткан бәндәсе булуына бөтен дөнья халкы ышанды». Бу аңа Тәңредән иңдерелгән миссия була. «Алга бар — дөньяны яулап ал!» «Чыңгыз хан турында Ихлас Кыйсса»да («Сокровенное Сказание о Чингиз-хане») аның юлы шулай дип бәян ителә.

Чыңгыз хан үзенең корал көче белән бөтен дөньяда тынычлык урнаштырырга омтылган. Аны Ходай җитәкли, дөрес юлын күрсәтә дип инанган ул. Моңа ышанырга да мөмкин, чөнки ул фантастик җиңүләргә ирешкән. Яшь Тимучин үзенең таланты аркасында Чыңгыз хан булып җитешкән. Атасы бик яшьли гүр иясе булган, аннан соң вассаллары терлек-туарларны, мал-мөлкәтне алып кайсы кая качып киткән. Яшүсмер ныгып җиткәч, үз тирәсенә нукер дусларын туплаган, мал-мөлкәтне кире кайтарган, һәм төрле ырулар аңа елыша башлаган. Шулчак күрше-күлән борчуга калган. Торгутайның 30 000 җайдагы Тимучинның 13 000 җайдагына каршы чыккан һәм, бер тапкыр һөҗүм ясап, аны тар-мар итәрмен дип ниятләгән. Тимучин үз гаскәрләренең флангларын бер яктан — атлылар үтеп кермәслек урман белән, ә сулдан көймәле арбалардан һәм йөк арбаларыннан торган саклану системасы белән ныгыткан, бу арбаларга дошманның игътибарын читкә юнәлтер өчен хатын-кызлар һәм яшүсмерләр куелган. Торгутайга маневр өчен җай калмаган, бөтен гаскәре үзәктә урнашканга күрә, ул Тимучиннан көчсезрәк булып калган. Сугышның ничек бетәсе инде Тимучинның гаскәри сәләтенә генә бәйле булган. Ул беренче мәртәбә җиңеп чыккан. Аннан инде башка җиңүләр тезелеп киткән һәм, ниһаять, 1203 елда ул хан булып киездә күтәрелгән, хан дип игълан ителгән. Чыңгыз хан 1227 елда вафат булган. Егерме бер ел идарә иткән дәвердә төрледән-төрле монгол һәм төрки кабиләләр чәчелеп яшәгән җирләр аның Евразия империясенә әверелгән. Ханлыгының башлангыч чорында Чыңгыз хан буйсынуында 13 000 арба булган, ә гомеренең азагына бөек ханга төрле телләрдә сөйләшкән һәм төрле диннәргә инанган 720 халык буйсынган. Бу чакта ул япа-ялан чүлләрне генә түгел, куәтле дәүләтләрне үзенә буйсындырган. Лев Гумилев билгеләп үткәнчә, «ул чакта монголлар 200 меңгә якын булган, ә калган ярты миллионы 1201 — 1210 елларда монголлар яулап алган кераитлардан, найманнардан, мәркитләрдән һәм татарлардан торган. Монголия тирәсенә урнашкан дәүләтләрдә халык гаять күп булган. Таңгут патшалыгында 2 миллион 500 мең кеше яшәгән, шуларның 500 меңгә якыны гаскәриләр булган. Кытайда, Кинь (Цинь) чжурчжэнь династиясенә буйсынган Төньякта һәм Көньякта — 80 миллион, Хәрәзм солтанлыгында — 20 миллионга якын, Көнчыгыш Европада — 8 миллион чамасы». Чыңгыз хан саны буенча үз халкыннан йөзләгән тапкырлар артыграк булган илләрне һәм халыкларны буйсындырган, моны бернинди дә мантыйкка сыйдыру мөмкин түгел. Монгол далаларында халык саны аз булу белән бергә Кытай һәм Азия белән чагыштырганда икътисад та бик зәгыйфь булган. Мондый җиңүләрне көч куллану, мәрхәмәтсезлек белән генә аңлату мөмкин түгел. Бу — Тәңренең әмере.

Шундый ук вакыт эчендә — «үзгәртеп кору» заманында — Русия үз территориясенең иң шәп яртысыннан мәхрүм калды, Каспий һәм Кара диңгезләрдә контролен югалтты, ә Балтыйк диңгезендә беренчелегеннән колак какты. Ул икътисади һәм хәрби куәтен җуйды. Тарихта төрле шәхесләрнең рольләре төрлечә языла. Берәүләрнең миссиясе җирләр туплау булса, икенчеләрнең — алдагы буыннар төзегәнне җимереп бару.

> *«Идел өстендә, корбанын эзләп, карчыга оча. Көчле җилгә күкрәген куеп рәхәт чигә. Ул каршылык ярата. Җил көчәйгән саен, ул өскә омтыла. Шәфәкъ кызыллыгы урман-кырларны, судагы дулкыннарны яктырта. Кояш баюын күзәтеп, карчыга офык аръягына — Көнбатышка атыла. Аның шәүләсе баеп баручы кояш белән бергә зәңгәр күкләрдә эреп югала. Ишарәләр безнең белән янәшә яши, алар — безнең тирә-юньдә».*

Чыңгыз ханның нәсел гербы — тырнакларына козгын кыстырган шоңкар, әмма ул үзе Мәңгелек Күк Тәңрегә табынган.

Тәңречелек — бөтен төркиләрнең традицион дине, ул җитәрлек дәрәҗәдә абстракт һәм гади булган. Һуннар инде Тәңре ханга, Югары дөнья хуҗасына табынганнар, аларның символлары кояш, ай, биек агачлар, бигрәк тә яшен суккан агачлар булган. Аеруча Урта дөнья иясе «Изге Йир-Су» культы көчле саналган. Хәтта Җирне «чакыручы», ягъни Җиргә мәдхия багышлаучы һун «сихерчеләре» булган. Һун пантеонының үзенчәлекле персонажы — «йол Тәңре». Мәет күмгән чакта һуннар, иң әйбәт киемнәрен киеп, ат чабышлары, егетләр белән кызлар арасында уеннар оештырганнар, шуннан соң яшь-җилкенчәкләрнең ата-аналары

балаларын өйләндерү турында сүз кушканнар. Борынгы төркиләрдә (көнчыгышта да, көнбатыш болгарларында да) дин һуннарның күзаллауларына тәңгәл булган.

Тәңри өчүк бизке бол,
Идел йөрим а беңгү бол.

Тәңре — дөньяны яралтучы, бар нәрсәнең чыганагы һәм сәбәбе. Ул җирләрне, күкләрне һәм шуннан аста бөтен нәрсәләрне яралткан. Ул кешеләрне яралткан, ул аларның яклаучысы, ул — бөек яклаучы көч. Аннан мәрхәмәт һәм рәхәтлек иңә. Тәңре акыллы җан иясен яралткан, аны җирдә яшәсен өчен «кеше» дип атаган. Әмма кеше Ходайга бурычлы икәнен онытканн, ул үзен аңа тиңли башлаган, аның белән ярышырга керешкән. Шулчак Тәңре бу кешене җир асты дөньясына — караңгылыкка ташлый һәм аңа Эрклиг дип исем бирә. Шуннан соң Тәңре тагын тугыз кеше яралткан, һәм хәзерге кешеләр шуннан үрчегән.

Тәңре каганнарга акыл һәм хакимият иңдергән, халыкка каганнар бүләк иткән, каганнарга каршы йөргәннәргә җәза җибәргән һәм каганнарга дәүләт эшләрен, хәрби эшләрне хәл иткәндә ярдәм иткән.

Төрки Тәңреләр арасында «ала атлы йол Тәңре» һәм «кара атлы йол Тәңре» дигәннәре дә искә алына. Алар, Тәңренең илчеләре буларак, кешеләргә «кот» — «Тәңре рәхәте, рух — җан» җибәргәннәр һәм «Тәңре ил» дәүләтне төзүгә этәргәннәр.

*«Мин — тәкъдирләр Тәңресе! Көнен дә, төнен дә мин ала атка атланып чабам!» Ул кешенең ике айлык улына каршы чапкан. Алар очрашканнар. Кеше куркып калган. Тәңре әйткән: «Курыкма! Мин сиңа кенәзлек рәхәтен бирәм!» Шулай дигән ул!»*

*«Фал китабы». X гасыр*

Чыңгыз ханның иманы Күк Тәңре булган, аңа башка инанулар да кергән, шуңа күрә ул бүтән диннәрне дә ихтирам иткән. Фарсы тарихчысы Җүвәйни язуынча: «Ул төрле юнәлешләрдәге галимнәрне һәм дәрвишләрне ихтирам итә иде, аларны Ходай каршындагы арадашчылар дип саный иде, мөселманнарга да, христианнарга да хөрмәт белән карый, потларга табынучыларны да җәберләми иде. Аның балалары һәм оныклары арасыннан берничәсе үзләре теләгән динне сайлап алды: берәүләре исламны үз итсәләр, икенчеләре христиан общинасына кушылалар, кайберләре потларга табыналар, ә инде беркадәре ата-бабалардан калган борынгы йолаларны үтиләр һәм бер якка да тайпылмыйлар, андыйлары бик аз кала. Төрле диннәргә күчсәләр дә, алар шәфкатьсезлектән читтә булалар, Чыңгыз ханның ясасыннан тайпылмыйлар, ә хан ясасы буенча бөтен диннәр дә бертөрле дип санала һәм алар арасында аерма ясалмый». Хәзерге заманда Европадагы корольләрнең берәр баласы исламга күчсә яисә мөселман шәехенең баласы христиан яисә буддист булып китсә, бик гаҗәп булыр иде.

Үзенең коточкычлыгы белән мәгълүм Варфоломей төнендә («озын пычаклар төне») католиклар Парижда меңләгән гугенотны бүтән дин тотканнары өчен генә рәхимсез рәвештә суеп чыкканнар.

Чыңгыз ханның бөтен диннәргә дә тигез карашы соклануга һәм ихтирамга лаек, барлык мәгърифәтле кешелек дөньясы бүген шуңа омтыла. Чыңгыз ханның үткен акылына, алдан күрә белүенә гаҗәпләнерлек: ул бит урта гасырларда үзе яулап алган җирләрдәге барлык диннәргә карата тигез караш урнаштыра алган.

Чыңгыз ханга мондый зирәклек кайдан килгәндер — әйтүе кыен, Кытай монахлары белән корган әңгәмәләренең файдасы тигәнме яисә ул үз дәүләт диннәре булмаган төркиләр традицияләрен дәвам иткәнме. Мәсәлән, уйгурлар арасында буддизм, зороастризм, несторианлык һәм манихейлык таралган булган һәм руханилар салымнан азат ителгәннәр. Бәлки, Чыңгыз ханга бу зирәклек Ходай рәхмәте булгандыр. Мөхәммәд пәйгамбәр белән Чыңгыз хан арасында ниндидер уртаклык бар. Икесе дә укый-яза белмәгән, әмма икәве дә гыйлем алуга бик ихтирамлы булган. Алар чыккан кабиләләр ярым кыргый булсалар да, тәкъдирнең рәхмәте белән, җәмгыятьне дөрес оештыру һәм югары әхлак нәтиҗәсендә ярты дөньяны яулаганнар. Әмма Мөхәммәд һәм аның тарафдарлары дөньяны ислам исеме белән үзләренә каратсалар, Чыңгыз хан диннәрнең тигезлеге өчен җан аткан. Ләкин шул гадәте аны империя төзүгә этәргән дип фаразлау дөрес булмас иде. Диннәргә тигез караш, билгеле инде, дәүләтне ныгытуга ярдәм иткән, әмма тарихтан билгеле булганча, еш кына империя дини әләмнәр астында төзелә. Мисал итеп христиан Византиясен яисә гарәп хәлифәтләрен искә төшерү дә җитә. Әмма Чыңгыз ханга хас «экуменизм»ның вакыты җитмәгән әле һәм соңрак аның үз халкы — монголлар — ламаизм кабул иткәннәр, ә Алтын Урда Үзбәк хан дәверендә мөселман дөньясына әверелгән.

Бөтен җиңүләрдән соң да, кешелек дөньясы тарихындагы иң зур дәүләтнең чикләнмәгән хакиме булгач та, Чыңгыз хан күкләрдәге бөек көчкә тулысынча буйсынганын һәм үзен Ходай кулындагы корал икәнен сизгән һәм аңлаган. Алай гына да түгел, ул һәркем Тәңрегә ышанырга тиеш дип санаган, шуңа күрә дингә аеруча әһәмият биргән. Үз бурычын җиренә җиткереп һәм куркусыз үтәр өчен кеше үз шәхси язмышының Ходай тәкъдирендә булуына җаны-тәне белән ышанырга тиеш. Шул рәвешле ул курку-өркүләрдән һәм

дөньялык шаукымнарыннан арынган. Шуңа күрә Чыңгыз хан барлык дини учреждениеләрне салымнан азат иткән. «Татар-монгол изүе» чорында православиене җәберләгәннәр дип язучы авторлар бик гади нәрсәләрне дә белмиләр. Бу хәл нигездә мөмкин түгел. Болай дип уйлау чыңгызчылар хакимлеге, ягъни «татар-монгол изүе» булмауны тануга тиң. 1312 елда Үзбәк хан тарафыннан Алтын Урданың дәүләт дине дип исламны игълан итү дә урыс кенәзләренә кагылмаган. 1313 елда Үзбәк хан Русь митрополиты Петрга ярлык тапшырган, анда түбәндәге сүзләр язылган: «Әгәр кем дә кем христиан динен хурлый икән, чиркәүләр, монастырьлар һәм часовнялар турында яман сүзләр әйтә икән, ул кешене үлем җәзасы көтә». Бу җәһәттән Үзбәк хан хатыны Тайдула аеруча аерылып торган, аны кеше арасында «христиан яклаучысы» дип атаганнар. Теләсә нинди дингә ихтирам чыңгызчылар сәясәтенең нигез ташын тәшкил иткән. Бу аның бөтен казанышларына һәм идарә системасына хас, шуңа күрә дә анда дини бәрелешләр булмаган.

> *«Чыңгыз хан һәм аннан соңгы ханнар попларга һәм «кара» халыкка шулай ук мәрхәмәт күрсәттеләр: алардан ясак та, терлек азыгы да алмадылар, алар исә безнең өчен уң яклары белән дога кылсыннар. Һәм без аларның грамоталарын беренче мәртәбә алмадык, аннары митрополитка грамота җибәрдек.*
>
> *Аннары Ходайга дога кылганда ясак түләмәүчеләр, терлек азыгы бирмәүчеләр безнең өчен үтенсеннәр. Яисә чиркәү җирләрен, суларын тартып алмыйбыз, яшелчә бакчаларын, йөзем бакчаларын, кышлауларны, җәйләүләрне биләмибез, алган тәкъдирдә дә кире кайтарабыз, ә чиркәү осталарына тимибез, китаплары законда кала, йә шул китапларны тартып алмыйбыз, ертмыйбыз һәм юк итмибез, мәсхәрәләмибез.*
>
> *Мондый грамотаны күргәннәр һәм ишеткәннәр поплардан, «кара» халыктан ясак алмыйлар, таможня түләве сорамыйлар, әгәр алсалар, гафу сорарга яисә үлем җәзасына дучар ителергә тиеш. Ә попныкылар безнең өчен Ходайга дога кылсын, әгәр дә уң ягыгыз белән дога кылмасагыз, гөнаһы сезгә булыр. Ул кеше дә гафу үтенер һәм үләр».*
>
> *«Мәнгү Тимернең митрополит Кириллга ярлыгы».*
> *1267, 10 август*

Диннәргә тигез караш культура элементы буларак татар дөньясында озак еллар сакланып килгән Казан ханлыгы чорында урыс һәм әрмән кварталлары булган. Явыз Иван Казанны яулап алып, мәчетләрне җимереп, православие чиркәүләре салдыргач кына, ислам каршы тору идеологиясенә әверелгән.

Җир йөзендә мессианлыкның төрле рәвешләре яшәгән. Европа культурасының нигезендә «Рим рухы» миссиясе ята. Дөньяның бөек диннәре, иң беренче чиратта, иудаизм, христианлык һәм ислам Җир шарында яңа дәвер башлануга этәргеч булган. Алар башлангычында ук мессиячел булган. Яһүдләр һәрвакыт үзләрен мессиячел халык дип санаган. Христианлык та төрле рәвешләрдә шундый ук дәгъвалар белән чыккан. Мөхәммәд пәйгамбәр чып-чын мессия булган. Немецларда фашист мессианлыгы коточкыч рәвешләр алган. Мессианлыкка гомер-гомергә уңай һәм тискәре күренешләр хас. Рим законнары, корал көчен кулланып булса да, Европа хокукыятенә нигез салган. Британлылар үзләренең казанышларын колонияләренә көчләп такканнар, соңыннан бу казанышлар җирле культураның бер өлешенә әверелеп киткән. Испан культурасы, конкистадорларның коточкыч гамәлләренә карамастан, Латин Америкасының табигый өлешенә әверелгән. Монда билгеле бер дәрәҗәдә объективлык, котылгысызлык, зарурлык булган, югыйсә яулап алучылар киткәннән соң, халык көчләп тагылган кыйммәтләрдән ваз кичәр иде.

Христианлык күкләрдән кешеләрне берләштерер өчен иңгән, исламның да миссиясе шундый ук. Бу диннәр бөек империяләр барлыкка китергәннәр, әмма кешелек дөньясын берләштерә алмаганнар. Чыңгыз хан да шул ук миссияне башкарырга керешкән һәм ул уңышсыз булып чыккан. XX гасырда кешелек дөньясы шушы мәгълүм чиккә килеп җиткән. Бүгенге көндә АКШ халыкара мөнәсәбәтләрнең кысаларын билгеләүче бердәнбер держава миссиясен үз өстенә ала, әмма цивилизацияләр бәрелеше аркасында бу максат тагын тормышка ашмас, ахрысы.

Глобальләштерү авторлары, теләсәләр дә, теләмәсәләр дә, билгеле бер мессианчылыкка дәгъва кылалар. Алар Көнбатыш кыйммәтләрен кайчак дәлилләп, кайбер очракта җәмгыятьтәге процессларны үзләре аңлаганча мәҗбүриләп тагу юлы белән бөтен дөньяга тараталар. Демократия кайчакта бөтенләй демократик булмаган ысуллар белән көчләп тагыла. Глобальләштерү идеясендә Чыңгыз ханның рухы — бөтен дөньяга хакимлек итү хыялы — кабат-кабат чагылып китә.

Көч кулланып кертелгән яисә дин, идеология, Интернет ярдәмендә урнаштырылган хакимлекләр арасында кайбер уртаклык бар. Шушы нәрсә бердәм закон яисә бердәм кыйммәтләр кертүгә, бер генә культура таратуга омтыла. Ә мондый күренеш, гадәттә, милли, территориаль, дини, этник, локаль культураны як-

лау рәвешендә җавап реакциясе кузгата. Бу ике мең ел элек тә, мең ел элек тә шулай ук булган. Дөнья бүген дә шундый ук.

Һуннар килеп нигезен дер селкеткәнче, Рим империясе дә мәңге сыман тоелган, Римның җимерелүе замандашлары өчен Ходай каргышы буларак кабул ителгән. Багдадны татарлар яулап алгач, бу вакыйга Гарәп хәлифлеге халкын да шулай ук тетрәндергән. Монгол империясе дә таркалган. Ә Мәскәү, Алтын Урда кыйпылчыклары өстендә яңа империя корганда, аны мәңгелеккә төзим дип ышанган. Империяләр юкка чыкса да, аларның шәүләсе кала. Рим империясен — Көнбатышның Изге Рим империясендә һәм Көнчыгыш Рим империясендә — Византиядә торгызырга, габбаслылар Багдад хәлифлеген, мәмлүкләр Каһирәдә һәм Оттоман империясендә үз империяләрен торгызырга тырышып караганнар. Монгол империясе Кытайда һәм Русиядә яңадан торгызылган. Аларның язмышы да шулай ук таркалуга дучар булган. Әмма бөек яулаучыларның шәүләләре безнең арада йөри, безнең аңыбызга үтеп керә һәм бөек империяләрне торгызу кебек тормышка ашмас хыялларга этәрә. Бердәм универсаль дәүләт төзү идеясенә каршылык кебек үк, Чыңгыз хан рухы да җиңелми һәм бирешми.

Таң Тәңре келти,
Таң Тәңре ози келти...
Таң Тәңре
Ядлы япарлы
Яруглы яшуглы
Таң Тәңре,
Таң Тәңре...

## Хәрби сәнгать

*Төрки халык! Үкен! Күрәчәгеңә күрә үзеңне күтәргән Билгә каганыңа, изге илеңә үзең түбәнлек кылдың, начарлык эшләдең. Коралланган гаскәр сине кудымы, сөңгеләр белән килеп куркыттылармы? Изге Өтүкән ешлыгыннан, халык, син үзең киттең. Элгәре Көнчыгышка бардык, Көнбатышка йөредек. Барган җиреңдә сине көткән рәхәтлек ул икән: каның сулар кебек акты, сөякләреңнән таулар өелде, бәк ир балаларың кол булды, сөлектәй кызларың колга әйләнде...*

Күлтәгин истәлеге. Олы язма. 735

Хәтта яхшы аналитиклар да Чыңгыз ханның бөек җиңүләре сәбәпләрен башка культуралардан эзләргә тырышалар. Генерал М.И.Иванин «Чыңгыз хан һәм Аксак Тимер заманында монгол татарларының һәм Урта Азия халыкларының хәрби сәнгате һәм җиңүләре» дигән махсус әсәрендә болай дип яза: «Азиядә несториан христианнары күп булганга күрә, мөгаен, алар анда гражданлык һәм мәгариф чаткылары алып килгәннәр һәм римлыларның, грекларның хәрби сәнгате турында кайбер белешмәләр хәбәр иткәннәр, ә бу белешмәләр монголларга да тапшырылган булырга мөмкин. Мәгърифәтле Кытайның күршедә генә булуы монголларга хәрби сәнгатьнең төрле тармакларын өйрәнү өчен шәп мәктәп булгандыр, күрәсең, ә бу заманнарда хәрби сәнгать Кытайда камиллек дәрәҗәсенә җиткерелгән булган». Генерал М.И.Иванин монголларның гаять зур уңышларының һәм даими җиңүләренең төп сәбәбен нәкъ менә шунда күрә. Галимнәр Чыңгыз ханның уңышларын цивилизацияле халыкларның теләсә кайсына чәпәп куярга омтылалар, ә «кыргый» монголларны һәм «варвар» татарларны бу җәһәттән гел читкә этеп куялар. Камил хәрби сәнгате һәм иксез-чиксез күп халкы, бетмәс-төкәнмәс икътисади куәте булган Кытай ни өчендер бөтен сугышларда җиңелеп килгән. Алдан ук ялгыш фикер йөртү һәрвакыт мантыйкка хилаф булып чыга шул.

Хикмәт бит бөтенләй бүтәндә. Хәрби сәнгатьнең һәм дәүләтчелекне коруның үз төрки традицияләре булган, нәкъ менә шулар монгол татарларының уңышларына нигез салган да инде, ә Кытай белгечләре, җиңүләрнең сәбәбе түгел, алар бары тик киңәшче, ярдәмче ролен генә үтәгәннәр. Монгол татарларының бөтен стратегиясе, тактикасы, коралланышы, тәэминаты, идарә системасы үзенеке һәм үзенчә була. Кытайларның һәм Азиядәге башка халыкларның армиясе даими һәм еш кына ялланган армия, ә төркиләрнең һәм монгол татарларының армиясе иррегуляр була, ул үз-үзен тәэмин итеп тора, ә сугыш алып бару билгеле бер хәрби катламның гына түгел, барлык халыкның да яшәү рәвешенә әверелә. Җүвәйни болай дип язган: «Дөньядагы бер генә гаскәр дә татарныкы белән тиңләшә алмый, алар хәтта (хәрби) эш арасында да кыргый җәнлекләр ауларга вакыт табалар; тыныч һәм ял көннәрендә үзләрен сөт, йон һәм башка файда бирә торган сарык көтүе кебек тоталар; ә хезмәт һәм бәхетсезлекләр вакытында бу халык бүлгәләнми һәм берберсенә каршы тормый. Мондый гаскәр, төрле вазифалар үтәп тә, халыкны азык-төлек белән тәэмин итеп тә, боерыкларны берсүзсез үтәүче крестьяннар сыман булган... Дошманнардан куркыныч яный калса дип яисә баш күтәрүчеләр килеп чыгу ихтималы булса дип, алар кирәге чыгарлык барлык нәрсәләрне әзерләп

куйганнар: корал-мазар дисеңме, байракларга, энә-җепләргә, чаптар һәм йөк атларына, ишәк, дөяләргә кадәр әзер торган. Шулай итеп, унлыклар да, йөзлекләр дә үз бурычын белгән һәм жиренә житкереп үтәгән, ә карап тикшерү көнендә алар коралларын, кирәк-яракларын күрсәтеп чыкканнар, берәр нәрсәсе житмәгән яугирне оятлы иткәннәр, тиешле җәзасын биргәннәр».

Монгол татарларының дала гадәте буенча барлык гаскәре атлы армия булган. Европада да, Азиядә дә мондый төр армия төзелмәгән. Рим легионерлары күбесенчә җәяүле яисә атлы арба кулланган, кыска кылычлар һәм кыска сөңгеләр белән коралланган. Тәре йөртүчеләр, гаять авыр коралланып, рыцарьлар тирәсенә җыелганнар һәм авыр корал йөртүче атлы гаскәр беренче һөҗүмдә үк җиңәр дип өметләнгәннәр. Монгол татарлары гаскәрләре исә бик хәрәкәтчән һәм гаять житез булган. Ә Русьта гаскәрләрнең нигезен дружина тәшкил иткән. Гаскәри берләшмәләр башында кенәзләр торган дружиналар җыелмасы оештырылган. Чолгап һәм камап алу, үз вакытында чигенә белү һәм резерв тоту тактикасына урыслар татарлардан өйрәнгәннәр. Монгол татарларының сугыш кирәк-яраклары башкаларныкына бөтенләй охшамаган. Ияр, өзәңге, жиңел кылыч — төркиләрнең иҗат җимеше. Ук-җәя ише коралга килгәндә исә, аңа охшаш нәрсә дөнья йөзендә булмаган һәм ул төркиләргә һуннардан мирас булып калган. Европадагы җәя зур һәм авыр булган, аның бер очын җиргә кадап куеп кына атарга мөмкин. Ә төркиләрнең җәясе төрле өлешләрдән тора, жиңел һәм бәләкәй, аннан атта килеш ату бик җайлы. Монгол татарларына, чыннан да, кытайлардан һәм башка халыклардан кергән нәрсә — кальгаларны яулап алу техникасы һәм алымнары, гәрчә Енисей кыргызлары моны IX йөздә үк эшли белгәннәр.

Монгол татарларында хәрби эшне оештыру ул заманда Европа һәм Азия халыкларындагы барлык мәгълүм булган рәвешләрдән бик нык аерылып тора. Генерал М.И.Иванин моны аңламаган шул. Кытайларның монгол татарларын хәрби сәнгатькә өйрәтмәгәнлеге көн кебек ачык, чөнки аларның мондый типтагы армиясе булмаган. Чыңгыз хан Кытай хәрби системасына да, Европаныкына да түгел, төркиләрнекенә таянган.

Төрки дәүләтләрдә хәрби эшне оештыру үз заманы өчен идеаль булган диярлек. Түргәш каганына омейдяд хәлифе Һашим (724 — 743) илчесе буларак килгән тарихчы ибне әл-Факиһ каганны исламга күчәргә кыстаган, һәм мөселманнар — шул ук шәһәр кешеләре алар, араларында мунчачылар да, тегүчеләр дә, итекчеләр дә булырга мөмкин, дигән. Шуннан соң каган берничә көн көтеп торырга кушкан, «үзе атка атланды, аңа байрак күтәргән 10 кешесе иярде. Һәм миңа да үзе белән барырга кушты. Без агачлар уратып алган калкулык янында туктадык. Кояш чыгуга, ул үзен озатып йөрүче ун кешенең берсенә байрак күтәрергә кушты, һәм байрак кояш нурларында ялтырап китте... Һәм шунда ук меңләгән атлы җайдак пәйда булды, алар «Чах! Чах!» дип оран салды. Һәм калкулык итәгенә рәт-рәт тезелде. Ун байрак та җилферди башлагач, калкулык итәгендә йөз мең атлы гаскәр калкып чыкты, алар баштанаяк коралланган иде. Шулчак каган тылмачка әмер бирде: бу илчегә әйт һәм ул үз чиратында әфәндесенә тапшырсын: минем яугирләр арасында мунчачылар да, итекчеләр дә, тегүчеләр дә юк. Әгәр алар исламны кабул итсәләр һәм аның барлык кануннарын үтәсәләр, нәрсә ашарлар икән соң?»

Бу «он ок бодын» («ун ук») берлегенең хәрби-административ оешмасын күрсәтү булган. Байраклар гаскәрләр өчен үзенчәлекле сигнал хезмәтен үтәгән, яугирләр исә аларга карап эш йөрткән, ягъни һөҗүмгә ташлану, бер урыннан икенчесенә күчү, чигенү һ.б.лар турында шул рәвешле фәрман алганнар. Яугирләр белән идарә итүнең мондый алымнары һуннар заманында ук кулланыла башлагандыр, мөгаен. Кытай тарихчылары ачыклаганча, безнең эраның II гасырында һун юлбашчыларының берсе «Копинен, кайда гына булмасын, үзенең штандартын (үз байрагын) югары күтәргән һәм үз кешеләренә фәрманнарын барабанда дөбердәтеп тапшырган». Хәрби гамәлләр катлаулана барган саен, бигрәк тә үз гаскәрләренең маневрга осталыгы, камалышлар кору, резервны эшкә җигү сәләте бәрабәренә һәрчак җиңеп килгән монгол татарларында байрак роле, димәк ки, аны саклау да намус-вөҗдан эшенә әверелгән, чөнки аннан гайре гаскәрләргә идарә итү мөмкин булмаган. Байракларга сакчыл мөнәсәбәт нәкъ менә шул рәвешле барлыкка килгән, һәм бу гадәтне тора-бара дөньяның башка халыклары да үзләштергән.

Төрки хәрби сәнгатьнең үз тәшкилиятләре булган. Иң беренче нәүбәттә хәрби корал һәм хәрби кием, саклану чаралары, ул заманда болар иң яхшылардан саналган. Яугиргә һәм атка көбә кидереп саклау системасы сугышчының чагыштырмача жиңеллеген аның хәрәкәтчәнлегенә тәңгәлләштерергә мөмкинлек биргән, ә Европа рыцарьлары моңардан мәхрүм булган. Кышын яугирләр җәнлек тиресеннән тегелгән колакчын бүрек һәм даха — ике катлы тиредән йонын тышка каратып тегелгән тун киеп йөргәннәр, мондый тун яугирләрнең тезләрен дә суыктан саклаган. Аякларына киез оек өстеннән читек кигәннәр, тора-бара ул итек дип атала башлаган. Сугышчыларны зәмһәрир суыклар да, хәлне алырлык эссе көннәр дә өркетми, алар өчен аяк астында атларына ризык булмау гына куркыныч.

Монгол татарларының иң олы горурлыгы — ат: үзе чыдам, үзе житез, үзе талымсыз. Атларны сугыш эшләренә махсус өйрәткәннәр. Яугир яраланган очракта ат, аның янына ятып, аңа ияргә атлануны җиңеләйткән, аннары хуҗасын сугыш кырыннан алып чыга белгән.

Кайбер хәрби берәмлекләрнең атлары билгеле бер токымда һәм төстә булган, бу сугыш вакытында гаскәрләргә идарә итүне җиңеләйткән. Бу да борынгы төрки гореф-гадәт. Сымя Цянь болай дип яза: «Сөнниләрнең җайдаклары көнбатыш якта булсалар — барысының да аты ак төстә, ә көнчыгыш яктагыларның барысы да ак борынлы соры атка атланган, төньяктагылар — чем-кара атларда, көньякта торучылар җирән атларда һөҗүмгә әзер». Күренекле һун юлбашчысы Баһатурның Кытай императорын җиңүен елъязмачылар түбәндәгечә тасвирлый: «Татарларның ак, соры, кара һәм туры атлары дошманга дүрт яктан дүрт колонна булып ябырылдылар». Һуннар башлаган бу традицияне соңыннан төркиләр һәм монгол татарлары үз иткән. Батый ханның урыс кенәзләреннән салым рәвешендә билгеле бер төстәге атлар таләп итүе дә мәгълүм.

Һәрбер яугирнең гаскәр белән янәшәдә ял итеп баручы 3 — 4 запас аты булган, бу бер урыннан икенче урынга күчүне җиңеләйткән һәм атны махсус ял иттерүнең кирәге калмаган. Һәрбер яугирнең кечкенә генә палаткасы булган, әмма алар атта килеш тә йоклый алганнар. Алар ун көн буена үз ризыкларын гына ашаганнар: үзләре белән корт, каклаган ит һәм беркадәр он һәм тары йөрткәннәр. Атлар исә азык-төлек чыганагы булган: бер ат 100 ир-атның тамагын туйдыра алган. Монгол татарлары армиясенең йөге аз булган, шуңа да алар калкулык-тауларны ансат кына кичеп чыкканнар. Кайвакыт үзләре белән көтү-көтү терлек тә йөрткәннәр. Армия гадәттә дошман исәбеннән тәэмин ителгән. Халыктан кирәк-ярак җыеп алу мөмкинлеге булмаса, ауга чыкканнар. Болар бар да бөтен бер армиягә зур тизлектә хәрәкәт итәргә мөмкинлек тудырган. Мөхәммәт, Җәбе һәм Сөбәдәй дошманны 20 меңлек армия белән айлар буе куып барганда, тәүлегенә, кайчак әле көндезге ялсыз гына, 120 шәр чакрым юл узарга туры килгән. 1241 елгы Венгр кампаниясе вакытында Сөбәдәй үз гаскәре белән 435 чакрым араны өч тәүлектән дә кимрәк вакытта уза торган булган. Бу юлларда аларга елгалар-күлләр, таулар кичәргә дә туры килгән. Елганы камыштан үрелгән салларда кичеп чыкканнар, шул салларга бөтен кирәк-яраклар тутырылган. Салларны ат койрыгына бәйләгәннәр, ә кешеләр кабартып тутырылган сарык турсыкларында йөзгәннәр. Теләсә нинди каршылыкны үтеп чыга алу һәм теләсә нинди һава шартларында сугыш алып бару сәләте татарлар хакында гайре табигый һәм гыйфрит кыяфәтле дип уйларга мөмкинлек биргән.

Урта Азия походы заманнарыннан монгол татарлары гаскәрләрендә кытай хирурглары булган. Яугирләрнең киемнәре ефәктән. Ук атып тидергән очракта ефәк ук белән бергә тартылып килгән, ефәк укның кадалу көчен киметкән һәм эләккән очракта да укны тартып алу ансатрак булган. Һәр яугир иптәшенә ярдәм күрсәтергә тиеш, кирәге чыкса, ашата, эчертә, әгәр берәрсенең угы яисә ук тутырган садагы төшеп калса, аннан арттарак килүче җайдак аның әйберләрен иелеп алып хуҗасына илтеп биргән.

Хәрби сәнгатьнең тагын бер мөһим тәшкилияте — яугирне өйрәтү. Багдад тарихчысы ибне әл-Җаһиз (869 елда вафат булган) төрки яугирне болай дип тасвирлаган: «Ул, бар көчкә атта чапкан килеш, артка да, алга да, уңга да, сулга да, аска да, өскә дә бертигез дәрәҗәдә оста ата. Ул, (гарәп) — хариҗит — бер укны җәясенә тарттырганчы, ун ук атып өлгерә. Ул хәтта таудан төшкәндә дә, далада чакта да атында томырыла гына, хариҗит исә тигез урында гына чаптыра ала. Төркинең күзе дүртәү — икесе маңгаенда, икесе артында». Буыннан буынга даими күнегүләр ясау хәрби осталыкка өйрәтүнең билгеле бер системасын тудырган: монгол татарларының бер гадәти яугире теләсә нинди бүтән армиянең биш-алты гаскәриен җиңә алган.

Хан гаскәре ауга чыкты.
Кыр кәҗәләрен камап алды.
Хан аларны үз кулы белән тотты.
Гаскәрнең шат авазы яңгырады!

*«Фал китабы». X гасыр*

Чыңгыз хан ауга чыгуны хәрби хезмәткә өйрәтүнең иң яхшы мәктәбе дип санаган. «Яса» болай ди: «Хәрби эштән бушаган арада, һичшиксез, аучылык белән шөгыльләнергә һәм гаскәрне шуңа күнектерергә кирәк. Максат бит аучылык түгел, ә яугирләрне чыныктыру һәм ук атарга, идарә итәргә өйрәтү. Кышкы ау аеруча мөһим саналган. Ул бөтен бер хәрби корпусның катнашуын таләп иткән, чөнки ерткычларны, антилопаларны һәм башка җәнлекләрне, куып тотып, кулга төшерергә кирәк булган. Мондый кампания вакыт-вакыт икешәр-өчәр айга сузылган. Ау чаралары белән хан үзе идарә иткән, бер генә җәнлекне дә камалган урыннан ычкындырырга ярамаган һәм хан иң беренче ату хокукына ия булган. Бу чакта кулга төшкән җәнлекләрнең бер өлеше киләчәктә үрчесен өчен ирекккә җибәрелгән.

Шушы күнекмәләрне исәпкә алсаң, монгол татарларының аз гаскәр белән дә дошманның биниһая армиясен тар-мар итә алуы аңлашыла башлый. Мәсәлән, Русьта 100 меңнән артык сугышчы булган — монгол татарларыныкына караганда гаять күп, әмма Русь армиясе начар өйрәтелгән. Дружиначылар үз кенәзләрен, аларның туганнарын һәм мал-мөлкәтен сакларга өйрәтелгән, ә менә эре хәрби тупланмалар составында алар сугыша белмәгән. Кенәзләр үзләре дә хәрби сәнгатьне белмәгән. Алар дружина башында су-

гышка ташланганнар, еш кына батырларча һәлак булганнар. Монгол татарларының гаскәр башлыгы яу барышында яугирләрдән читтә торып аларны күзәткән. Аның вазифасы — тиешле карар кабул итү, гаскәрләргә идарә итү, кече командирларга ярдәм күрсәтү. Монгол татарларының югары дәрәҗәдәге гаскәр башлыклары арасыннан бик сирәге яу кырында ятып калган. Колонна янында Чыңгыз ханның төпчек улын үтергәннәр, бу — Көнбатыштагы барлык сугышлар барышында чыңгызчылар арасындагы беренче һәм бердәнбер югалту булган. Көнчыгыш Европадан походтан кайтып баручы Җәбе яу кырында түгел, авырып үлгән.

Гаскәр башлыклары үз сугышчыларын булдыра алганча ныграк сакларга тырышканнар. Маңгайга маңгай сугышып җиңү мөмкинлеге зуррак булган очракта да алар азрак югалтуларга китерәчәк тактика корганнар. Батый хан Венгриядә Пешт тирәсендә, гадәттәгечә, дошман гарнизонын тигез җиргә хәйләләп чыгарырга тырышып караган. Ниһаять, архиепископ Уголан җитәкчелегендә бәләкәй генә отряд шәһәр капкасын ачып чыккан, сугышка керергә тырышып караган, әмма монгол татарлары сазлык урынга таба чигенгән, ә авыр кораллар таккан венгр гаскәриләре шунда кереп бата башлаган, һәм монголлар, аларны камап алып, йөзгә-йөз торып атып бетергәннәр. Төркиләрнең угы европалыларныкы белән чагыштырганда никадәр ераграк оча алганны да искә алсаң, аларның бернинди югалтуларсыз венгрларны кырып салганнарын күз алдына китерүе кыен түгел.

Монгол татарларының тактикасы яудан яуга кабатланып торса да, шушы илнең, шушы урынның үзенчәлекләренә бик оста яраклаштырылган һәм дошманның өстенлекләре дә, кимчелекләре дә бик җентекләп исәпкә алынган. Төркиләрнең хәрби традицияләренең бер үзенчәлеге — аерым өлешләрнең үзара мөнәсәбәте. Чыңгыз ханга кадәр бер генә армия дә сугыш барышында гаскәрләренә идарә итү осталыгын белмәгән әле. Атлы җиңел гаскәрне — авыр коралланган гаскәр белән, кинәт кенә һөҗүм башлауны ялган чигенү тактикасы һәм флангларны камап алу белән аралаштыру монгол татарларына һәрчак җиңү алып килгән.

Шайо елгасындагы сугыш — шуның ачык мисалы. Венгрлар монгол татарлары гаскәрләрен туктату өчен күперне саклау җитә дип санаганнар, әмма Батый ханның бу җирләрне венгрларның үзләреннән әйбәт белүен исәпкә алмаганнар. Гаскәрләрнең бер өлеше күпер саклаучыларга таш атучы җиде коралдан һөҗүм иткән, еракка атучы артиллерия бүген дә нәкъ шулай эшли. Шул рәвешчә, һөҗүмнең төп юнәлеше шунда дип уйларлык шартлар тудырылган һәм король гаскәрләре барысы да шунда ташланган. Ләкин шулчак ханның төп көчләре агым буйлап өскә юнәлгән һәм венгрларны тулысынча камап алган. Әле шуннан соң да алар маңгайга маңгай һөҗүменә күчмәгәннәр, дошманнарына җәяләрдән һәм ташаткычлардан атканнар, венгрлар арасында буталыш һәм паника башланган, аннары аларны чигенү өчен тар коридор аша уздырганнар. Венгр гаскәрләренә идарә итеп булмый башлаган, алар качарга тотынган, монгол татарларының җайдаклары, венгр сугышчыларын уңга да, сулга да җибәрмичә һәм бер үк вакытта чигенүчеләрне берәмберәм ата барып, аларның хәрәкәтенә идарә иткән. Венгрлар мондый марштан бөтенләй хәлдән тайгач, монгол татарлары һөҗүмгә күчкән һәм дошманнарын тураклап бетергән. Төрле мәгълүматларга караганда, бу сугышта 40 меңнән алып 70 меңгә кадәр венгр сугышчысы һәлак булган һәм король армиясе бөтенләй юк ителгән. Венгрия шул рәвешле буйсындырылган.

Кампанияләргә уңышны хәрби сәнгать кенә дә, яу барышында идарә системасы гына да түгел, төрле фронтларда сугыш алып баручы армияләрнең үзара яраклаша белүе, элемтәдә торуы да китергән. Чыңгыз хан гаскәрләрендә элемтә идеаль була, кайвакыт аның камиллеген аңлатып бирү дә кыен. Сөн державасын яулап алганда, Чыңгыз хан бер армиясен берничә ел алдан көньякка җибәргән. Бу армия, кытайларны урап узып, көнчыгыш Тибет чүле һәм Һималай тавы сыртлары аша, юл өстендәге Тонкин илен яулап алып, Аннам патшалыгына ясак салып, максатына таба хәрәкәт иткән. Бу вакытта гаскәр яугирләренең биштән дүрт өлешен югалткан, сирәгәйгән гаскәрләрен һинд-кытай халкы исәбенә тулыландыра барган. Армияләр арасы гаять ерак булуга карамастан, Чыңгыз хан Сөннәр державасына бер үк вакытта көньяктан да, төньяктан да һөҗүм ясап өлгергән.

Әдәбиятта, гадәттә, монгол татарлары ябырылуы турында язалар. «Курыкканга — куш» ди халык. Запас атлар саны күп булганга күрә, шундый тәэсир калгандыр, мөгаен. Марко Поло сүзләренә караганда, аларның саны унсигез тирәсе булган. Зур походлар алдыннан, күрәсең, шулай булгандыр да ул (һәр яугиргә өч-дүрт ат билгеләнгән). Мондый очракта, чыннан да, 400 мең дип саналган гаскәрдә нибары 20 меңләп яугир булган, бу әллә ни күп түгел. Юлындагы барлык азыкны, чәчүлекләрне, фуражны кырып-себереп ашап барган 400 000 атлык көтү тәртипсез ябырылыш кебек тоелгандыр шул. Бу күзаллау чынлыкка туры килми, билгеле.

Кагыйдә буларак, монгол татарларының гаскәрләре дошман гаскәреннән сан ягыннан шактый калышкан. Кытай һәм Урта Азия походларында Чыңгыз ханга бермә-бер артык дошман көче каршы чыккан. Ул гаскәренең күплеге белән түгел, оешканлыгы һәм хәрби әзерлеге белән җиңеп килгән. Гаять югары дәрә-

җәдәге хәрәкәтчәнлек дошманның хәлсез звеносына һөҗүм итеп, аның төзек рәтләрен аз көч белән тар-мар итәргә һәм өлешләп-өлешләп кырып бетерергә ярдәм иткән.

Батый ханга Җучи олысына идарә итү тапшырылгач, олысның көнбатыш чиге яулап алынган илләр санына карап киңәя барган. Рәшидетдин таныклавына караганда, Чыңгыз хан Батый хан идарәсенә 4000 монгол гаиләсен тапшырган. Яугирләрнең калган өлешен һәм кирәк кадәресен ул үзе буйсындырган халыклар арасыннан табып алырга тиеш булган. Билгеле, Европага поход монголларның барысы өчен дә уртак, әмма калган мәшәкатьләр Батый хан өстенә төшкән. Сугыш кампанияләрен нәтиҗәле уздыру өчен ул бу 4000 яугирне үз полководецлары арасында бүлгән, һәрберсенә 1000 әр җайдак билгеләгән. Бу очракта ниндидер ташкын булып ябырылып килүче гаскәрләр турында сүз йөртү мөмкинме соң?

Теләсә кайсы хәрби кампаниягә Чыңгыз хан озаклап әзерләнгән, һәрвакыт разведканы алдан җибәргән, географияне, дошманның мөмкинлекләрен, гаскәрләрдәге фикер сөрешен җентекләп өйрәнгән, каршы якның теләсә нинди җитешсезлеген күреп алырга һәм мөмкин кадәр күбрәк кулланырга тырышкан. Моның өчен шушы илгә илчеләр, шулай ук сәүдәгәрләр, кәрванчылар яисә сукбайлар рәвешендәге белгечләр алдан җибәрелгән. Һөҗүмнең төп юнәлешләре, гаскәрләрнең җитешсезлекләре, кампанияне башлау вакыты билгеләнгән, кайвакыт махсус имеш-мимешләр таратылган. Бик кирәкле очракларда сугышып разведка ясау, көтүлекләрне, елгаларны, кальгаларны билгеләп, дошманның каршы тору сәләтен бәяләп, һөҗүм итү юллары ачыкланган.

Бөтендөнья хәрби тарихында Сөбәдәй һәм Җәбе җитәкчелегендәге өч төмәннән торган экспедиция корпусының Көнчыгыш Европага разведка операциясе уникаль санала. Алар сугыша-сугыша Кавказ тауларына барып чыкканнар (1222), шунда грузин патшасы Георгий Лаша аларны туктатырга тырышып караган һәм тар-мар ителгән. Аннары гаскәрләр, Дарьял шарлавыгы аша үтеп, Кубань елгасының үрге агымына — кыпчаклар тылына барып чыкканнар, тегеләре исә чигенгәннәр һәм урыслардан ярдәм эзләгәннәр. Шуннан соң монгол татарлары Кырымга бәреп кергән, Судак кальгасын яулап алган, Калка елгасына килеп чыккан һәм шунда урысларның һәм кыпчакларның 70 меңлек берләшкән көчләрен тар-мар иткән. Кайтышлый Идел Болгарстанына һөҗүм иткән, җиңелгән һәм кире Азиягә таба борылган, Чыңгыз ханның төп көчләренә килеп кушылган, Чыңгыз хан исә бу вакытта хәрәзмшаһлар дәүләтен тар-мар китергән һәм аны Иртыш елгасының үрге агымында көтеп алган. Шул ук вакытта Җучи дә Сөбәдәй белән Җәбенең имин кайтуын тәэмин итәргә тиеш булган: ул аларны Арал диңгезе һәм Түбән Идел ягыннан каплап торган. 6500 чакрым озынлыктагы разведка рейдын узып, Сөбәдәй Батый ханның Көнчыгыш Европадагы киләчәк җиңүләре өчен план әзерләгән, бу күп кенә илләрнең язмышларында тирән эз калдырган. Әзерләнгән операцияләрнең колачы гаҗәпкә калдыра, аның өчен бит Евразиянең төрле өлешләрендә берьюлы сугыш алып баручы берничә армиянең хәрәкәтен җайга салырга кирәк булган.

Монгол татарлары психологик операцияләр алымнарын да оста кулланганнар. Венгриягә таба чигенүче кыпчакларның 40 меңләгән гаиләсен эзәрлекләп килеп, янәсе, венгр короле Белега адресланган хатны шулар йөргән җирләргә бик оста гына китереп ташлаганнар. Хатның эчтәлеге кыпчаклар белән венгрлар арасына ут булып төшкән һәм аларның рухын какшаткан. Батый шулай ук кулга төшерелгән король почтасын, халыкка күрсәтеп, дошманын таркату максатында кулланган. Лигница янындагы яу барышында һөҗүмгә кергәндә монгол татарлары полякча оран салганнар: «Кем кая булдыра — качыгыз, качыгыз!» — дип, рыцарьларның башларын әйләндергәннәр. Алар илдәге дини каршылыкларны да, халыкның хөкүмәттән ризасызлыгын да үз файдаларына бора белгәннәр. Җәбе бер һөҗүме белән бөтен Кара Кытайны кулга төшергән, чөнки ул дини каршылыклардан бик белеп файдаланган.

Монгол татарлары үзләре бәреп кергән илне һәрчак бик әйбәт белгәннәр. Цзинь дәүләте белән сугыш алып барганда аларның Кытай җирләрен үзләре илендә сугышучы дошманнан да әйбәт белүләре ачыкланган. Плано Карпини язганча, монголлар Европаны 18 ел эчендә яулап алырга җыенганнар, бу аларның «юртаҗы» дип аталучы махсус генераль штабларының планнарны җентекләп әзерләве турында сөйли. Җиңә алмасын белсә, Чыңгыз хан сугышка кереп тә тормаган, әмма кампанияне башлап җибәргән икән, аның күңеленә бернинди шик-шөбһә дә үтеп керә алмаган. Чыңгыз хан улларына бик еш кабатлый торган гыйбарә бар: «Һәрбер эш азагына җиткерелсә генә лаеклы була».

Мин — иснәнеп ятучы юлбарыс!
Башым — камышлар эчендә!
Мин шундый кыю!
Мин шундый гайрәтле!

*«Фал китабы». X гасыр*

Чыңгыз хан тәхеткә күтәрелгән мәлендә монголларга гына идарә кылган, тора-бара аның гаскәрләренә кераитлар, найманнар, мәркитләр, татарлар, оратлар, кыргызлар һәм башкалар килеп кушылган. Цзинь бе-

лән сугыш башлаганнан соң шактый гына киданнәр, кытайлар, чжурчжэньнар, тангутлар аның ягына чыккан. «Армиянең этник составы гына түгел, сыйфаты да үзгәргән,— дип яза Е.И.Кычанов.— Кытай хәрби техникасы үзләштерелгән, беренче чиратта шәһәрләрне камау өчен ташаткыч артиллерия, дарылы катнашмаларның кабынып китүчәнлеге һәм шартлату сыйфатлары кулланыла башлаган. Көнбатышка поход вакытында кытай генераллары да катнашкан, Гао Мин поход планнарын әзерләгән, дипломат Ян Вэй-чжун Көнбатышның 13 дәүләтендә илче булган, Ши Тянь-линь поход барышында хөкемдар вазифаларын үтәгән. Көнчыгыш Европага таба монголлар гына түгел, монгол татарлары да (бу термин Кытай чыганакларында 1211 елда Цзиньга походлар башланганнан соң күренә башлый бугай, кытайның «мэн-да» дигәне тирә-яктагы халыкларның Монголия территориясендә яшәүче халыкны гомуми бер «татарлар» термины белән атавыннан килеп чыккан, күрәсең, бу этноним монголлар явы мизгеленә Русьта һәм Көнчыгыш Европада сакланып калган), монголлар буйсындырган башка халыклардан торган гаскәр дә кузгалган». Гаять күптөрле армияне куркытып һәм байлык белән кызыктырып кына сугышчан итеп булмый, болар бит нык ихтыярлы, курку белмәс һәм Чыңгыз ханга тугрылыклы яугирләр булганнар.

Чыңгыз хан кебек шәхес бик сирәк туа, шулай да аның армиясен җиңүләрдән җиңүләргә төгәл оешканлык һәм хәрби башлыкларны сайлап алып куя белү китергән. Чыңгыз хан сүзләренә караганда, аның югары дәрәҗәгә ирешүенең сәбәбе — кешеләрне сайлап алу осталыгында. Үзенең варисларына ул төрле урыннарга куелучы кешеләрне бәяләүгә зур игътибар бирергә киңәш иткән һәм, әгәр дә аның дәвамчылары идарә итү өчен лаеклы һәм сәләтле кешеләрне сайлый белсәләр, империя мәңнәрчә ел яшәр дип белдергән. «Чыңгыз хан, һәр кешенең сәләтенә карап, түрә урынын бирүен әйткән: батырларга һәм зирәкләргә гаскәрләрне ышанып тапшырса, булдыклыларга һәм исәп-хисап белгәннәргә — йөкләр саклауны, авыр сөяклеләргә терлек асрауны тапшырган. Аның сүзләренә караганда, унлыкка башлык була белгән кешегә меңлекне дә ышанып тапшырырга мөмкин. Монголлардан ул балаларын атта йөрергә, уктан атарга, көрәшергә, корал белән эш итә белергә өйрәтүне таләп иткән, чөнки югарырак урыннарга алар туган-тумачалыкка түгел, ә үзләренә таянып ирешергә тиеш дип санаган Чыңгыз хан». Чыңгыз хан алымнары түбәндәге гыйбарәдә дә бик ачык күренә: «Есүгәй — бәйгә тиң каһарман да, аның кебек эшкә оста кеше дә юк. Әмма ул үзе ару-талуны белмичә, эчәсе һәм ашыйсы килүен сизмичә бертуктаусыз эшли алганга күрә, нукерлардан һәм яугирләрдән дә шуны таләп итәчәк, ә үзе кул астындагыларның барысын да кыенлыкларга чыдам дип саначак, ә тегеләре бөтенләй бүтән бит. Шуңа күрә аны гаскәрләргә башлык итеп куярга ярамый. Үзе эчәсе, үзе ашыйсы килгән кеше генә башлык була ала, чөнки ул башкаларның хәлен аңлый һәм юлга чыкканда исәпле була, гаскәре ач-ялангач булмасын, терлек-туары арыкланмасын өчен кулыннан килгәннең бөтенесен башкара. Моннан мәгънә: юл һәм эш сезнең арадагы хәлсезрәкләргә карап исәпләнә». Монгол татарлары гаскәрләрендә командир (җиһангир) үз карарларын яугирләренең кәефенә карап төзәтә белгән һәм иң көчсезнең хәленә кергән.

Чыңгыз хан, варислары купшы һәм озын титуллар алмаса иде, хан исеме белән канәгать була белсә иде, дип теләгән һәм үз буйсынуындагы кешеләр белән әңгәмәләрендә варисларына исемнәре белән генә дәшәргә кушкан. Купшы титуллар кешене артык горур һәм мактанчык итәсен, моннан дәүләткә бернинди дә файда килмәсен белгән ул. Варисларының бик азы гына аның киңәшенә тугры калган шул.

Күк Тәңрегә иман китереп, Чыңгыз хан бөтен дөньяны тынычлыкка өндәгән: дәүләт-илләрне ачыктаначык буйсынырга чакырган, беркайчан да кисәтми-нитми һөҗүм итмәгән. Аңа викинглар мәкерлеге хас түгел. «Яса — халыкара хокукның төп нигезләмәләреннән берсе, үз ихтыяры белән буйсынган очракта халыкның иминлеген гарантияләп, сугыш игълан итүнең билгеле бер рәвеше ул». Иң соңгы кисәтү буларак, дип язган Чыңгыз хан, әгәр дошман буйсынмый икән, «Борынгы Тәңре ни кыласын без дә белмибез». Еш кына сугыш башлауның сәбәпчесе Чыңгыз хан үзе дә булмаган. Кинь империясе өч ел саен үз гаскәрләрен төньякны кырып-талап кайтырга җибәрә торган булган. Бу — «колларның санын киметү һәм кешеләрне юк итү» дип аталган. Ул чакта империядә ялчы итеп татар кызлары һәм малайлары тотмаган гаилә сирәк очраган. XIII йөз Кытай елъязмасы бик канәгатьләнеп болай дип яза: «Хәзерге вакытта татарларда вельможа булганнарның күбесе теге заманнарда кулга алынганнар. Татарлар Шамога (Гоби чүленә) качтылар һәм үч аларның миенә, канына сеңде». Татарлар һәм монголлар җавап итеп сугыш ачканнар. Кытайга яу чабар алдыннан Чыңгыз хан биек-биек тауга менгән һәм Күк Тәңрегә ялварган: «И Мәңгелек Тәңребез, мин агаларым Беркан белән Гемикай өчен үч алырга дип коралландым, аларны гиннар императорлары вәхшиләрчә үтерде. Әгәр минем гамәлемне хуплыйсың икән, миңа ярдәмеңне җибәр, ә җир йөзендәге рухларның яхшылары да, яманнары да дошманнарымны җиңәр өчен берләшсеннәр иде».

Монгол татарлары гаскәрләре еш кына үзләре үк бәрелешләрне читләтеп узганнар. Ә менә инде илчеләрен үтерсәләр, беркемне дә кызганып тормаганнар. «Хәтерлисездер,— дип яза Г.В.Вернадский,— илчеләрен Хәрәзмшаһ Мөхәммәт үтерткәннән соң, Чыңгыз хан 1219 елда Төркестанга поход белән чыга. 1223 елда монгол илчеләрен кыйнап ташлаганнан соң, урыс кенәзләре дә монголларның үченә тап була, шуның

нәтиҗәсе — Калкадагы һәлакәт». Илчеләр үлеме өчен үч алу изге гамәл саналган. Чыңгыз хан үз илчеләрен Мөхәммәткә бүләк-санаклар белән җибәргән, исәбе — тегеләр белән сәүдә бәйләнышлары урнаштыру. Сөйләшү буенча, сәүдәгә дип җибәрелгән сәүдәгәрләр кәрваны солтан әмере белән үтереп бетерелгән. Шуннан соң да әле Чыңгыз хан үз илчесе аркылы болай дип җибәргән: «Син бит миңа сәүдәгәрләремә тимәскә сүз бирдең; сүзеңдә тормадың, алдау падишаһка бер дә килешми. Әгәр сәүдәгәрләрем синең әмереңнән башка гына Отрарда үтерелгән дип ышандырасың килсә, Отрар хакимен миңа тапшыр, мин аңа тиешле җәзасын бирермен; югыйсә сугышка әзерлән». Ачуы чыккан Мөхәммәт илчене үтерергә кушкан. Ышанып килгән кунакларны үтерү иң куркыныч җинаять саналган һәм «Яса» буенча моның өчен үч алмый калырга ярамаган. Чыңгыз хан сугыш башлаган, Мөхәммәтнең төп көчләрен тар-мар иткәч, аңа чынлап торып ау оештырган. Ибне әл-Әсир болай дип яза: «Көферләр Сәмәркандны яулап алгач, Чыңгыз хан,— Алланың бәддогасы төшсен аңа,— 20 мең җайдагын безнең өскә җибәрде һәм мондый әмер бирде: «Хәрәзмшаһны кайда гына булса да эзләп табыгыз — хәтта күккә ашкан булса да табыгыз һәм тотып алып кайтыгыз». Сөбәдәй белән Җәбе шәһәр арты шәһәр буйсындыра барганнар, зур гарнизоннарны әйләнеп узганнар, бер җирдә дә туктап тормаганнар, солтанга тын алырга да ирек бирмәгәннәр, аны бер утрауга куып кертКәннәр, һәм солтан шунда вафат булган.

Генерал М.И.Иванин версиясе болай: имеш, кәрванны һәм илчеләрне Отрар хакиме Каир хан вәхшиләрчә үтермәгән, ә Чыңгыз ханның хәрби разведкасы, сугыш башлар өчен сәбәп итеп, үзе провокация оештырган. Чыңгыз хан бит бөтен җиңүләрне аңа Күк Тәңредән бирелгән дип санаган.

Мин — алтын канатлы ерткыч бөркет!  
Минем тәнем өчен табыш әле бетмәгән!  
Мин диңгез буенда яшим,  
Үземә ни ошый — шуны эләктерәм!  
Үземә ни тәмле — шуны ашыйм!  
Менә шулай көчле мин!  
Мин — ерткыч бөркет!  
Яшел кыя — җәйге оям!  
Шушы тауларда яшим һәм шатланам!

*Бөркет мактануы*  
*«Фал китабы». X гасыр*

Чыңгыз ханның һәм аның гаскәр башлыкларының хәрби сәнгате иң биек үрләргә ирешә, кешелек дөньясында аны әле беркемнең дә уздыра алганы юк. Наполеон көннәрнең берендә болай ди: «Мин Чыңгыз хан кебек бәхетле була алмадым». Чыңгыз хан беркемнең дә буе җитмәслек булып калачак та, чөнки империяләр заманы узды.

Чыңгыз хан сугыш кампанияләрен уздыруның һәм дәүләт коруның даһие була. Сугышлар гомер-гомергә барлык иҗтимагый системаны яңартуга китергән. Кыргый яисә начар оешкан халыклар җитди сугышта җиңүгә ирешә алмаганнар. Колачлы сугышлар алып бару сәләтенә карап җәмгыятьнең һәм дәүләтнең үсеше турында фикер йөртергә мөмкин.

Чыңгыз хан Евразиядә мөмкин булган бөтен географик һәм климатик зоналарны, икътисади системаларны, төрле мәдәниятләрне, диннәрне һәм телләрне берләштергән. Алтын Урда башкаласы Сарай-шәһәрдән алып Монгол империясе башкаласы Каракорымга кадәр дүрт айлык юл үтәргә кирәк булган. Урта гасырларның коммуникация системалары белән мондый гаять зур дәүләткә идарә итү мөмкинлеген күз алдына китерүе дә кыен.

Монгол яулап алучысының төп принцибы — милли традицияләрне саклап калу, аларны үстерү һәм метакультурага китереп кушу. Чыңгыз хан мәдәнияттә берни дә көчләп такмаган, төрледән-төрле халыкларны коммуникация чаралары һәм диннәргә ихтирам аша берләштереп барган. Аның заманында тауарлар һәм мәгълүмат алмашу бик көчәеп киткән, чөнки Евразиядә йөзләрчә еллар буена тынычлык һәм бер-береңә ихтирам урнашкан. Ул үзен чынлап торып даһиларча тоткан, ул «бөтен нәрсәне юктан бар иткән» (Жан Жак Руссо фикеренчә). Аның даһилыгы башка халыкларның мәдәни казанышларын сеңдереп кенә калмаган, ә аларны тагы да үстергән, ул чит-ят нәрсәне үзенеке итә белгән, шул ук вакытта милли кыйммәтләрне бөтендөнья дәрәҗәсенә күтәргән — аерым халыкларның казанышларын бөтендөнья байлыгына әйләндергән. Төркиләр эзләп табып башлап җибәргәнне һәм игълан иткәнне Чыңгыз хан бөтендөнья мәдәнияте элементына әверелдергән. Шул ук вакытта ул, гыйлемле кешеләрне җыеп, аларны бер идея — дөньяның бердәм дәүләтен төзү идеясенә хезмәт итәргә мәҗбүр иткән, яңалыкка һәм заманча нәрсәләргә гаять сиземле булган. Аның даһилыгы да, тиңдәшсезлеге дә нәкъ менә шунда, чөнки бүгенге көнгә кадәр шуннан да олпат дәүләт төзү омтылышы уңышка ирешмәде әле.

В.Я.Владимирцев исәпләвенчә, «Чыңгыз хан системасының иң зәгыйфь ягы — цивилизацияне күчмә тормыш белән яраштыру планнары, шулай ук аның ыру-нәселе беркайчан да таркалмасына, империядә «Күк Тәңре» кодрәте белән аның «Кагыйдәләренә», аның мәңгелеккә яраклы «Яса»сына таянган очракта, хан җитәкчелегендәге дус-тату дәүләткә идарә итүгә бәхәссез өмет һәм ышаныч. Тегесе дә, монысы да хыял гына булып чыккан, цивилизацияне күчмә тормышка яраклаштырып булмаган кебек, Чыңгыз ханның «Яса»сына карамастан, ыру-нәсел бердәмлеге төрле сәбәпләр аркасында какшый барган». Күчмә мәдәният тә — шул ук цивилизация, әмма аның роле пространство һәм вакыт белән чикләнгән. Ул — бүтән мәдәният, ул утрак, шәһәр, мөселман һәм христиан мәдәниятләре белән очрашкан һәм җиңелгән. Әмма башкалардан начаррак булган өчен түгел, тарихи миссиясе тәмамланганга күрә генә. Дала цивилизациясе турындагы тарихи сюжетның фаҗигасе дә нәкъ менә шунда, әмма Чыңгыз хан рухын гына һаман да җиңеп, юкка чыгарып булмый, чөнки ул,— барлык уңай һәм тискәре яклары белән бергә, экспансиягә мәңгелек омтылыш. Чыңгыз хан рухы җимергеч инстинкт түгел, киресенчә, бик олы иҗтимагый системалар төзүгә омтылыш, теләсә нинди мәдәни һәм дәүләти чикләрне җиңеп чыгу. Чыңгыз хан дөньясы — киртәләрсез-чикләрсез дөнья, ул үзара дини һәм этник тигезлек, бөтендөнья тарихының төп максатына,— Николай Бердяев сүзе белән әйткәндә,— Көнчыгыш белән Көнбатышны берләштерүне хәл итүгә корылган. Чыңгыз хан рухы — яңа гыйлемнәргә омтылучы һәм шуларны бөтендөнья халыкларына таратучы системаның һәркем өчен ачык булуы.

*Александр Македонский Һиндстанга бәреп кергән һәм шунда киләчәкне әйтеп бирә торган йог турында ишеткән. Ул тау мәгарәсенә шул йог янына юнәлгән һәм, аның медитацияләвенә комачаулап: «Син киләчәкне күрә беләсең икән?» — дип сорау биргән. Йог, медитациясен дәвам итеп, баш кына чайкаган. Шунда Александр, түземсезләнеп, аны гамәленнән тагын бүлдергән: «Мин Һиндстанны яулап алырмын микән?» — дигән. Йог әкрен генә күзләрен ачкан да бик кызганып Александрга карап алган һәм: «Ахыр чиктә сиңа алты терсәк озынлыгындагы җир кисәге генә кирәк булачак»,— дигән.*

## Ислам

*Сиңа вәхи иңде күктән —*
*Ул — Коръән... син Коръәнне*
*Илләргә тарат, әмма дә*
*Рәнҗетмә кяферләрне!*

*Әллә кем ди үзен кеше...*
*Җиргә килә — бичара,*
*Бар гомере — тик бер сулыш,*
*Гүргә иңә — бичара!*

*Үзе теләгәнчә Аллаһ*
*Үтерә йә терелтә —*
*Бәндә яшисе һәр мәлне*
*Санап тора ул күктә.*

*Чын дөнья — теге дөньяда —*
*Шул аргы якта икән,*
*Анда гел алма-хөрмәләр*
*Шау чәчәк ата икән...*

*Тик фәрештә ике тапкыр*
*Өрер Сур мөгезенә —*
*Килер акылга сыймаслык*
*Афәт дөнья йөзенә.*

*Туган качар туганыннан*
*Һәм сабые — анадан...*
*Ходайга кайтып ялварыр*
*Һәммәсе дә яңадан.*

А.С.Пушкин
«Подражание Корану». 1824
Зөлфәт тәрҗемәсе

X гасырда гарәп географы ибне Хәүкәл Сырдәрья буйлап күченеп йөрүче мең төрки гаиләнең ислам диненә күчүе турында хәбәр итә. 960 елда Карахан дәүләтендә 200 мең гаилә ислам динен кабул иткән. Ис-

лам Карахан һәм Сәлҗук дәүләтләрендә киң таралып, төрки дөньяда яңа сәяси һәм мәдәни вазгыять тудырган.

Ислам Хәзәр каганлыгына һәм Болгарстанга моннан бераз алдарак үтеп керә. 903 һәм 913 еллар арасында язылган ибне Рустә шәһадәтнамәсе буенча, «Болгарның Алмыш исемле ханы ислам дине тота», ә илнең халкы турында ул болай дип язган: «Аларның күпчелек өлеше ислам дине тота, авылларында мәчетләре һәм башлангыч мәктәпләре, мәзиннәре һәм имамнары бар». Ислам динен рәсми дин итеп сайлап алу Хәзәр каганлыгы белән көрәш зарурлыгынан да килеп чыга. Идел Болгарстаны Хәзәр каганына салым түләп торган.

921 елда Идел Болгарстаны хакиме — Шилке углы Алмыш-әлтабар үзенең Габдулла ибне Башту әл-Хәзәри исемле илчесе аркылы Багдад сараена хәлифкә үтенеч хаты юллаган, «аны иманга китерүче, ислам кануннарын өйрәтүче, мәчет төзеп бирүче һәм ханның үзе өчен мөнбәр ясап, шул мөнбәрдән аның исеменнән үз илендә һәм аның дәүләтенең барлык өлкәләрендә хөтбә урнаштыручы бирәр кешене җибәрүләрен» сораган. Моннан тыш хан «патшалардан һәм дошманнардан саклану өчен кальга төзүне» үтенгән.

Хәлиф күбрәк вакытын күңел ачып үткәргән, шәрабтан да баш тартмаган, аның янына керү бик кыен булган. Хәлифнең ышанычлы хезмәтчесе Тәгин атлы төрек ярдәмгә килгән. Ул Хәрәзмдә тимерчелек белән шөгыльләнгән һәм үз тауарын угыз һәм башкорт илләренә саткан, шуңа күрә ул якларны яхшы белгән. Күпмедер вакыт Болгар патшасында да яшәгән. Алмыш ханның хаты хәлифкә аның аркылы барып җиткән, хатка Идел Болгарстанына ярдәм итүнең сәяси яктан отышлылыгын шәрехләгән язма да беркетелгән. Моңа каршы булган Хәрәзм шаһы әйтүенчә, «хәлифнең күзенә төтен җибәрелгән».

Болгар патшасы югары катламы яһүд динендә булган хәзәрләрдән саклану өчен кальга төзүне үтенгән. Алмышның улын Хәзәр каганы әманәт рәвешендә үзендә тоткан. Ул гына да түгел, Хәзәр каганы әлтабарның кызларын бер-бер артлы үзенә хатынлыкка таләп итеп алган. Моның өчен Алмыш хан аңа аеруча ачулы булган. Болгарлар исламны дәүләт дине итеп кабул иткән очракта Хәзәр илендә оешкан көчле мөселман фиркасе тагы да көчәеп китә алган. Хәзерге Көнбатыш Казахстан җирендә яшәүче угызларда гаскәр җитәкчесе Әтрәкнең сүзе аларның башлыгы — ябгу сүзеннән үтемлерәк булган, ә ул исә Болгар патшасы белән туганлашкан һәм исламны кабул итүгә каршы килмәгән. Ә угызлар Хәзәр каганлыгына каршы булганнар. Сәяси вазгыять Алмыш ханны Болгарстанның бәйсезлеген игълан итүгә этәргән.

Хәлиф үзе дә Хәзәр каганлыгыннан канәгать түгел, чөнки 913 елда каган урысларны Каспий диңгезенә үткәргән, аларга баскынчылык итәргә мөмкинлек биргән, бу хәл халык арасында ризасызлык тудырган. Моннан тыш хәлифкә Идел буенча туры юл ачу отышлы булган, бу очракта ул Урта Азияне болгарлар белән сәүдә итүдән кысрыклап чыгара алган. Болар барысы да хәлиф сараен төньякта исламны ныгыту өчен ерак Болгарстанга илчелек оештырып җибәрергә мәҗбүр иткән.

Хәзәр иле һәм Болгарстан икесе дә Бөек Идел юлында урнашкан һәм аларның мәнфәгатьләре һәрвакыт бәрелешеп торган. «Шул ук вакытта,— дип яза А.П.Ковалевский,— Хәзәр каганына хәрби каршылык күрсәтергә көче дә, хәтта кальгасы да булмаган Болгарстан икътисади яктан үзен хәзәрләрдән шактый бәйсез тойган. Чөнки Идел аръягыннан Урта Азиягә кадәр коры җир буенча туры юл болгарлар карамагында булган. Алар үзләренең бар тауарларын Урта Азиягә сата алганнар». Тик барыбер әлтабар, табигый ки, хәзәрләргә бәйлелектән азат булуны өстенрәк күргән. Багдад белән мөнәсәбәтләр, ихтимал, сүздә генә булгандыр, әмма Алмыш аңа кирәкле халыкара абруй биргән. Өстәвенә әлтабар ислам ярдәмендә эчке хакимиятне дә ныгыткан. Ыруларның төп өлеше ислам тирәсендә берләшкән. Суварларның бер өлеше төшеп калган, алары да гади халыктан булган. Алар чуваш халкының нигезен тәшкил иткәннәр. Ә аксөякләр Алмыш ханга ияргән.

Алмыш ибне Фадлан илчелеге килүне үзенең абруен ныгыту өчен бик оста файдаланган, шул ук вакытта ул хәнифә мәзһәбендәге Урта Азия белән барлык сәүдә элемтәләрен саклап кала алган. Илчелекнең кальга төзергә акча алып килмәве моның өчен бик яхшы сылтау булган. Хәлиф акча вәгъдә иткән, ә илчелек акча алып килмәгән. Хәлиф акчаны үзенә бирәчәге булган вәзир Гали ибне әл-Фураттан алырга исәп тоткан. Ул вәзир исә хәлиф казнасын тулысынча туздырып бетергән һәм казнаны аның мөлкәтен тартып алып тутырырга туры килгән. Аның Бохарадагы ерак хуҗалыклары-җирләре калган, хәлиф шуларга исәп тоткан. Ләкин Бохарадагы ул акчаларны ала алмаган. Һәм илчелек Болгарга буш кул белән килеп төшкән. Алмыш ачуланган булып кыланган һәм шәфи мәзһәбен кабул итүдән баш тарткан. Сөйләшү болай булган.

«Ибне Фадлан әлтабардан сораган:

— Синең дәүләтең зур, акчаң күп һәм керемең дә шактый, нигә соң син кальга төзергә акчаны хәлифтән сорадың?

Әлтабар җавап биргән:

— Мин Ислам дәүләте бәхет китерә дип уйлыйм, чөнки бу дәүләтнең акчасы дини кануннар рөхсәт иткән чыганаклардан тупланган. Шул сәбәпле мин шундый үтенеч белән мөрәҗәгать иттем. Чынлап та, әгәр

дә мин кальганы үз алтыныма яки көмешемә төзергә уйласам, минем өчен бернинди кыенлык та булмас иде. Әмма миңа хак динлеләрнең хакиме акчасы ярдәмендә фатиха алу мөһим иде, шуңа күрә сорадым». Алмыш гамәлдә Хәзәр каганлыгыннан бәйсезлек алган һәм шул ук вакытта хәнифәчеләр белән дә калган.

Берничә елдан соң Багдадка Болгар патшасының улы җитәкчелегендәге илчелек килгән. Алар баш иеп сәламләү өчен Мәккәгә юнәлгәннәр һәм хәлифкә «әләм, савад һәм акча» алып килгәннәр. Ихтимал, Болгар белән Багдад арасында халыкара мөнәсәбәтләр шуның белән чикләнгәндер, әмма болгарлар күркәм ислам цивилизациясенең бер өлешенә әйләнгәннәр. Шәһәрләр, архитектура, гамәли сәнгать, әдәбият, фәннәр тизрәк үсә башлаган. Тел ислам категорияләре белән тулыланган.

Болгарлар исламның төньяк терәгенә әйләнгәннәр. Бу турыда күренекле акыл иясе инглиз Роджер Бэкон нәфрәтләнеп һәм шаккатып болай дип язган: «Аларга Мөхәммәд тәгълиматының барып җитүе чиктән тыш гаҗәп хәл...» Ул болгарларны «явыз сарациннар» дип атый, чөнки алар исламны кабул итеп кенә калмыйча, аны күрше халыкларга да таратканнар.

Шул ук елларда урыс кенәзлекләре арасында православие тарала башлаган, ә көнбатыштан католиклар дине үтеп кергән. Урыслар һөҗүме нәтиҗәсендә Хәзәр иле юкка чыккан, яһүд дине Идел буенда ныгып кала алмаган. XIII гасырга Евразиянең сәяси аренасында төп өч уенчы калган: ислам, православие һәм көнбатыштан рыцарьлар белән үтеп керә башлаган католиклар дине. Католиклар диненең мөмкинлекләре киңрәк булган. Әмма татар-монголларның барлыкка килүе көчләр нисбәтен тамырдан үзгәрткән. Православие салымнардан азат ителү аркасында ныгыр өчен көчле стимулга ия булган һәм нәкъ менә шушы вакытта мәҗүси төньякны христианлаштыру тәмамланган. Моннан соң ислам чираты җиткән.

Бәркә — исламны ачыктан-ачык кабул иткән беренче хан. Әлеге адымда дини генә түгел, сәяси мәнфәгатьләр дә — Алтын Урданың Монгол империясеннән бәйсезлек алуга омтылышы да яткан. Әмма чын «ислам революциясен» 1213 елда исламны дәүләт дине сыйфатында кабул итеп Үзбәк хан ясаган. Бу чыннан да революция булган, чөнки Чыңгыз ханның «Бөек Яса»сы бозылган һәм күп кенә морзалар мондый яңалыкка каршы булганнар: «Син бездән күндәмлек һәм буйсыну көтә аласың, ә безнең динебездә һәм иманыбызда синең ни эшең бар? Без Чыңгыз хан законын һәм «Яса»гын ни рәвешле ташлап, ничек гарәпләр диненә күчәрбез икән?» Мондый сүзләре өчен аларны җәзалап үтергәннәр. Далада беренче тапкыр дини карашлары өчен эзәрлекләү факты килеп чыккан. Әлеге күренеш утрак культураның күчмә культурадан күпкә өстен булуын һәм ырулардан өстен яңа этник бергәлек барлыкка килүен күрсәтә.

«Ислам революциясе»нең нәтиҗәләре тирәнгә китсә дә, урысларга кагылмаган. Монастырьлар элеккечә салым түләмәгән һәм шактый байлык җыйган. Салым түләмәс өчен еш кына монастырьныкы булмаган милекне дә яшергәннәр. Моның белән беррәттән мөнәсәбәтләрнең яңа яссылыгы барлыкка килгән — ислам һәм православие көндәш диннәргә әверелгәннәр.

Недаром вы приснились мне
В бою с обритыми главами,
С окровавленными мечами,
Во рвах, на башне, на стене.

Вы победили: слава вам,
А малодушным посмеянье!
Они на бранное призванье
Не шли, не веря дивным снам.

Прельстясь добычей боевою,
Теперь в раскаянье своем
Рекут: возьмите нас с собою;
Но вы скажите: не возьмем.

Блаженны падшие в сраженье;
Теперь они вошли в эдем
И потонули в наслажденье,
Не отравляемом ничем.

*А.С.Пушкин*
*«Подражание Корану». 1824*

Ислам дөньясының үзәге Багдад булган. Иран да ислам үсешенә зур йогынты ясаган. Бохара исә Үзәк Азияне тагын бер көчле рухани үзәк иткән. Әмма гарәп хәлифәте җимерелгәч, Көнчыгышта инициатива Госман империясенә күчкән. Истанбул барлык мөселманнарның мәркәзенә әйләнгән һәм, Олжас Сөләйманов язганча, «XI гасырда төркиләр, Византияне һәм гарәп илләрен буйсындырып, йолдызлы ярым айны ислам символы иткәннәр». Төрки-угызлар символы гомумислам символына әйләнгән.

Ислам тарихында Госман империясе авыр вакыйгаларга бәйле. Барлык империяләр кебек үк, ул күп конфессияле ил булган, гәрчә Истанбул барлык мөселманнарның мәркәзе булып саналса да. Империяне Европа экспансиясенә каршы торучы «реформалаштырылган» панисламизм принципларында үзгәртеп корырга тырышу традицион исламның һөҗүменә әйләнгән. Империядә милли җирлектәге конфликтлар көчәйгән һәм болар барысы да революциягә китергән. Кемаль Ататөрек дәүләтнең диннән аерылуын игълан итеп кенә калмаган, мөселман бергәлеген дошман итеп күргән. Вакыф милке национализацияләнгән, шәригать суды һәм мәдрәсәләр бетерелгән, суфый җәмгыятьләре таратылган. Хатын-кызлар ирләр белән тигез хокукка китерелгән, күп хатынлылык бетерелгән. Европача киенүгә, Европача ел исәбенә, Европа календарена күчү турында законнар кабул ителгән, гарәп алфавиты латин алфавитына алмаштырылган.

Иң радикаль әверелеш ясалган: дөнья тарихындагы иң соңгы ислам хәлифәте исламга ачыктан-ачык каршы дәүләткә әверелгән, ул исламга төрекләрнең Европа дәүләтләреннән артка калуының сәбәбе дип караган һәм бу бөтенләй үк нигезсез булмаган.

Татарларда исламның язмышы шулай ук фаҗигале. Алтын Урдадан соң килеп чыккан ханлыклар эзлекле рәвештә ислам юлыннан барганнар. Ләкин ул ханлыклар бетүгә йөз тотканнар, ә ислам үзе аларга котылу юлы күрсәтә алмаган. Казан ханлыгының күренекле шагыйре Мөхәммәдьяр болай дип язган:

Кяфер берлә мәмләкәт булмас хәраб,
Золым берлә екылыр улус йөдәп;
Көфер вә кәфир нәфсенә кыйлыр зийан,
Золым берлә булыр ил хәле яман.

Шагыйрь дәүләтне коткаручы идея сыйфатында гаделлек идеясен яклаган. Әмма вакыт төрки-татар дәүләтләре файдасына эшләмәгән. Казанны һәм башка ханлыкларны буйсындыру белән исламның вазифасы кискен үзгәргән, ул христианлаштыруга каршы тору символына әйләнгән.

Ислам юлында калган алпавытлар һәм морзалар үзләренең җирләреннән, мактаулы дәрәҗәләреннән, вазифаларыннан коры калганнар, ә православиегә күчүчеләр, табигый ки, урысларга әйләнгәннәр. Державин иң беренче чын урыс шагыйре булган, Карамзин Русия дәүләтенең Петрдан соңгы рәсми тарихын язган, Чаадаев — XIX гасырдагы оригиналь урыс фәлсәфәсендә бөтен бер дәверне башлаучы акыл иясе, Аксаков беренче славянофил булган, кенәз Йосыпов, Столыпинны үтереп, Русияне коткарып калган һ.б. Православиене кабул итүдән баш тартучылар татарлар булып калган, әмма аларны мөртәт язмышы көткән. Күпләр урманнарга, хәтта чит илләргә качканнар.

Мне от бабушки-татарки
Были редкостью подарки:
И зачем я крещена,
Горько гневалась она.

*А.Ахматова*
*«Сказка о черном кольце»*

Туган илләрендә калган татарлар бер-бер артлы баш күтәргәннәр. Башка милләтләр белән каршылык хакимият өчен куркыныч булган, бу вазгыять Екатерина II не 1773 елның 17 июнендә «Барлык диннәргә карата тигез караш һәм архиерейларга башка диннәргә кагылышлы эшләргә катнашуны тыю турында» Указ чыгарырга һәм шул рәвешле мөселманнар хокукын өлешчә танырга мәҗбүр иткән. Ислам әкренләп яңадан аякка баскан.

Татарлар алдында исән калу бурычы торган вакытта социаль нормаларны беркетү-җыю этносны саклап калуга хезмәт иткән, әмма заманалар үзгәргән. Тиз үсүче православие дәүләтендә татарлар алдында икътисади һәм сәяси шартлар югында да конкурентлыкка сәләтле булу бурычы торган. Бу башка парадигма таләп иткән.

Ул елларда татар фикере мөселман культурасы кысаларында гына яши алган, башка социаль институтлар тыелган. Дөньяви уку йортлары, газета һәм журналлар булмаган, белемле кешеләр, хәтта Аллаһының барлыгында шикләнүчеләр дә барыбер мәдрәсәләргә җыелганнар. Клублар, газеталар, журналлар соңрак — XX гасыр башында, ә татар дөньяви уку йортлары 1917 елгы революциядән соң гына барлыкка килгән. XIX гасыр башында исламга альтернатива булмаган. Әмма ислам дөньясы кешеләргә үз-үзеңне тотышның үрнәген күрсәтмәгән, ихтимал, киресенчә — урта гасырларның хәнифә мәзһәбе башка дөньядан кергән, ул татарларның проблемаларын хәл итә алмаган. Шул вакыт Курсави 1804 елда исламны яңартырга чакырган, ул халыкка өндәмә белән мөрәҗәгать иткән: «Сез чын һәм хак мөселманнар түгел. Сез Коръәннән һәм пәйгамбәр сүзләреннән тайпылдыгыз». Ул тәкълид (авторитетларга ияреп бару) урынына иҗтиһад, ягъни тәнкыйди, иркле фикер йөртүне тәкъдим иткән. Бу тарихи вазгыятьне яңабаштан аңларга мөмкинлек биргән.

Яңа заманда татарларның мөстәкыйль фикере нәкъ менә Курсавидан башланган. Аңа кадәр татарларның иҗтимагый фикере башкаларны кабатлаган, аны фәлсәфи яки рухани фикер дип тә әйтеп булмый, ул дөньяга гомуми караш элементларыннан торган һәм төрле әдәби һәм дини әсәрләр буйлап чәчелгән. Курсавины һәм аннан да күбрәк дәрәҗәдә Мәрҗанине үзенчәлекле татар фикеренә нигез салучылар дип атарга мөмкин.

Н.Трубецкой язганча, «төрки тирәлеккә эләккән дин, котылгысыз рәвештә катып кала һәм кристаллаша». Аннан соң Н.Бердяев «исламның хәрәкәтсезлеге» турында әйтә. Моны урта гасырлар чорына хас дип карарга була, әмма ислам татарларда үзенең сизгерлеген күрсәткән. Тормыш шартлары басымы астында, дәүләт катнашыннан башка, ислам үзенең эчке мантыйгы буенча үсеш алган. Татарларның бөтен иҗтимагый тормышын үзгәрткән җәдидчелек чоры җиткән. Бу чын-чынлап «ислам революциясе» булган. Исламга кабат төшенү дини тәгълиматтан башланган, аннан соң тарих мәсьәләләренә һәм этногенезга кагылган, һәм, ниһаять, мәгариф системасын үзгәртү чоры җиткән. Моннан соң матбугат, мәгълүмат чаралары, китап басу эше көчле үсеш алган. Татарның XX гасырдагы иң мәшһүр шагыйрьләре һәм язучылары, иң яхшы эшкуарлары, һәм, ниһаять, иң күренекле сәясәтчеләре җәдиди мәдрәсәләрдән чыккан. Тормышның шифалы җәдидчелек дулкыны кагылмаган даирәсе калмаган.

Ул елларда татар дини тәгълиматы универсаль булган, ул иҗтиһад, милли тарих, этногенез, заманча мәгариф системасы, хатын-кызлар хокуклары, сәясәт мәсьәләләрен тигез дәрәҗәдә куйган. Башка алга киткән халыклар өчен бу көнүзәк күренеш түгел, Европа милләтләре бу юлны иртәрәк узганнар, ә төрекләр әле төрек түгел, госманчылар булып кала биргәннәр, алар алдында әле үзләренең империк үзәкчелеген җиңеп чыгу торган. Татарлар Европадан өйрәнгәннәр. Мәрҗани әйткән: «Халкыбыз киләчәге өчен, үз эшләребезне мөстәкыйль башкару өчен, халкыбыз башка халыклар арасында югалып калмасын өчен безгә Европа фәнен, гыйлемен һәм һөнәрен үзләштерү зарур! Безгә Европа үрнәгендәге мәктәпләрдә уку үтә файдалы. Шушы мәлдә һөнәрләр һәм мәгърифәт чәчәк аткан җирдә белем алу һәркайсыбызга зарури. Фән һәм белем өчен милли чикләр һәм махсус тел юк!» Татар дини тәгълиматында иң күренекле, башкалар өчен мәгънәле, милли чикләрдән бик еракларга чыгып китә торган нәрсә — реформация идеясе, аның мантыйгы, фантастик колачлы нәтиҗәләре. Сәяси, гражданлык һәм икътисади хокуклары чикләнгән, тарих тарафыннан онытылган халык кинәт кенә дәүләттән бәйсез мәгариф системасын булдырырга һәм үстерергә көч һәм акча тапкан. Һәм нинди система! XX гасырга татарлар арасында укый-яза белмәүче кеше калмаган. Бу — татар эшкуарларының һәм җәдидчеләренең тарихи батырлыгы. Татар эшкуарлары яңа тармаклар булдырганнар, үз халкына ярдәм итү төзелмәләре оештырганнар, Азия, Себер, Кытай, Финляндия базарларын яулап алганнар. Татар фикере эшкуарлыктан тизрәк үскән, ул куәтле икътисади төзелмәләр булып гамәлгә ашкан. Үз халкын тергезү эшендә шушындый фидакарьлектән көнләшергә генә кала! Кызганыч, без бу традицияне югалттык. Бүген татар эшкуарлыгы шәхси байлык җыюга кайтып кала, ул революциягә кадәрге кебек социаль функцияләр үтәү белән мәшәкатьләнми. Ул нинди дә булса идеяләр, ачышлар, табышлар чагылдырмый. Бу исә иң түп шөгыле көн узгач акча санау гына булган кибетчене хәтерләтә. Болай язу аяныч, әмма чыннан да шулай бит. Шул кибетче шөгыленнән дә эчпошыргыч нәрсә бар микән?! Әлбәттә, татар газеталарына, клубларына, мәктәпләренә ярдәм итүче химаячеләр бар, әмма фикер югарылыгы, очыш сизелми.

Җәдидчелек кадимчеләр тарафыннан каршылыкка очраган, кадимчеләр үзләреннән соң бернинди дә кызыклы нәрсә калдырмаганнар. Хәер, бу — табигый. Алар сакчы функциясен үтәгәннәр, шул сәбәпле кадимчелек баштан ук гамәлдәге хакимияткә һәм үз халәтләренә күнгән ярлы, кимсетелгән кешеләрнең дөньяга карашын чагылдырган. Бу агымнан патшаның тикшерү хезмәтенә әләк ташучылар аз чыкмаган. 1910 елның 12 гыйнварында Идел буе төбәгендә татар-мөселман йогынтысына каршы чаралар оештыру буенча махсус киңәшмәдә болай билгеләп үтелгән: «Яңа ысулчыларның (җәдидчеләрнең) көчле оешмасы иске муллаларга үзләренә каршы көрәшергә ирек бирми», «иске муллалар халык училищелары директорлары исеменә җәдидчеләргә административ төстә тәэсир итүләрен сорап мөрәҗәгать иткәннәр». Киңәшмә иске тәкъва муллаларга ярдәм итүне хөкүмәтнең бурычы итеп күргән. Иң яхшы татар мәдрәсәләрен туздыру һәм күренекле татар мәгърифәтчеләрен кадимчеләр күрсәтүе буенча кулга алу — тарихыбызның хурлыклы сәхифәсе. Кадимчеләр милләтне түгел, ә үз катламнарын, үзләренең социаль дәрәҗәләрен яклаганнар, чөнки шулар исәбенә яшәгәннәр.

Петр Столыпин исламда прогрессив юнәлешнең киң таралуына нык хафаланган, ул биредә дини түгел, дәүләти көрәш чагылышлары күргән. Махсус киңәшмәнең утырышлар беркетмәсендә «Русиянең бер милләткә караган һәм төрле сөйләшләрдә булса да, нигездә, уртак телгә ия булган 15 миллионлык мөселман халкы хәзерге вакытта үз үсешенең яңа чорын уза, мәгърифәткә омтыла һәм, иске көнкүрешне җимереп, Русиянең мәдәни үзенчәлегенә янаучы яңа көнкүреш төзи» дип билгеләп үтелгән. Преосвященный Андрей әйтүенчә, «хәзерге вакытта Казан мәдәният һәм нәшрият эшләре үзәге буларак Константинопольдән мө-

һимрәк. Хәтта Төркестанда файдаланыла торган дәреслекләр дә Казанда, агалы-энеле Кәримовлар нәшриятында басылганнар». П.Столыпинны Русия мөселманнарының барысының да мәгърифәтче татар имамнары йогынтысына эләгүе борчыган. Үзенең Министрлар Советына күрсәтмәсендә ул болай дип язган: «Идел буеның, Урал алдының һәм Урта Азиянең татарлаштыруга дучар ителүче түбән культуралы, ярым утрак һәм күчмә халыклары гына түгел, барлык утрак халык татар йогынтысына бирелә. Моңа конфессиональ мәктәпләр (мәктәпләр һәм мәдрәсәләр) булышлык итәләр, алар мөселманнар яши торган җирләрне зур челтәр рәвешендә каплап алганнар. Татар һәм татарлаштырылган руханилар, аларга тәңгәл карашлы дөньяви укытучылар җитәкчелек иткән бу мәктәпләр хөкүмәтнең түбән уку йортларының гаять аз булуы җирлегендә мөселман культурасын һәм пантуран рухын ышанычлы таратучылар булып хезмәт итәләр». Ул куркынычны мөселман дөньясының эволюциясендә, аның урыс культурасына көндәшлегендә күргән, шул көндәшлек нәтиҗәсендә христианнармөселманлыкка күчкән. «Православиегә җитди зыян салган бу күчеш шул ук вакытта Идел буенда әхлакый өстенлекне татар-мөселман культурасы ягына авыштырып, милли-урыс башлангычына да сизелерлек сукты»,— дип дәвам итә Столыпин. Ул мөселман Диния Нәзарәтенең үзәкләшүен бетерергә һәм бер үк вакытта мәдрәсәләрдә урыс телен һәм гомумбелем бирү предметларын укытуны тыярга, башкача әйткәндә, аларны мәзһәб кысаларына кире кайтарырга тәкъдим иткән. «Минемчә, конфессиональ уку йортларында (мәктәпләрдә һәм мәдрәсәләрдә) гомуми белем бирүче барлык фәннәрне бетерүне хәзер үк билгеләргә кирәк. Моңа ярашлы рәвештә мәчетләр каршындагы һәм аерым шәхесләр яки иҗтимагый оешмалар кулындагы барлык мөселман мәктәпләре һәм мәдрәсәләре билгеле бер вакыт эчендә (бер ел) йә ябылырга, йә гомуми типтагы училищеларга үзгәртелергә, йә саф конфессиональ уку йортларына әйләнергә тиеш булырлар иде». Биредә реакцион урыс режимының һәм мәзһәб тарафдарларының мәнфәгатьләре туры килгән, болары да, тегеләре дә татар рухының яңаруында куркыныч күргәннәр. «Пантюркизм» дигән төшенчә гамәлгә кертелгән, ул йөз ел буена карачкы ролен үтәгән һәм хәзерге вакытта да файдаланыла. 1911 елда мөселман халкы арасында панисламчылык һәм төрек эмиссарларын тапмаган губернаторлардан П.Столыпин циркулярына җаваплар килә башлаган. Ә Иж-Бубый мәдрәсәсе буенча ачылган 12 томлык зур эш татарлар арасында пантюркизм һәм панисламчылык идеяләре таралуын дәлилли алмаган.

И Ходай! мәгълүм сиңа, тик яхшылыкта касдымыз;
Зикремездер: казы, кузы, яшь кенә кыз, кымыз.

Юкны сөйлиләр җәдидләр, чыннан да әһлинсафлә без,
Мактыйбыз ич Тәңремезне иштә бу биш «каф» лә без.

Ерак кыйл безне син афате нәфсә,
Мөдавим кыйл һаман кафате хәмсә.
*Г.Тукай*
*«Бер шәехнең мөнәҗәте». 1908*

Кайвакыт кадимчелекне халыкның үзенчәлеген, аның традицияләрен саклауга хезмәт иткән дип әйтәләр. Әлеге тезис шик тудыра, чөнки дин этник яктан сакланып калуның бердәнбер факторы түгел. Халык тәрбиясенең, дөньяви әдәбиятның, шулай ук дингә катнашы бик аз булган музыканың да өлеше зур. Керәшен татарлары белән мөселманнарны нәрсә бәйләп тора соң? Тел, музыка, сәнгать. Польша-Литва һәм Идел буе татарлары бергәлеген нәрсә тудыра? Дин генә түгел, юкса алар башка мөселман халыкларына кушыла алган булырлар иде, алар бит полякча сөйләшәләр. Димәк, музыка һәм сәнгать. Музыка күңелгә тирән үтеп керә ул, моны тотып карап та, күреп тә булмый. Музыканың ролен бу күзлектән бәрәү дә тикшермәгән, гәрчә аны бөтен сәнгатьнең башлангычы дип санап булса да. Шигырьдә ритм һәм моң булмаса, ул күңел кылларына кагылмый. Чын шагыйрь иң элек ритм эзләп, көйләп карый, аннан соң гына сүзләр барлыкка килә.

Без бишектән үк татарлар язмышы шикелле катлаулы мелизмнарга, борылышларга бай музыка ишетәбез. Озын көйләр гасырлар төпкеленнән килә, алар язма тарихтан күпкә иртәрәк барлыкка килгән һәм, мөгаен, алар әле татарның әллә ничә буынын кичерерләр. Бу җырларга ни салынган соң? Халыкның рухымы, тарихымы, киләчәгеме? Моны беркем дә белми. Кайчак шулай да була: берәр көй балачактан күңелгә кереп оялый да гомер буе шунда яши. Бакый дөньяга күчкәндә аңлыйсың: яшәр өчен сиңа шушы бер көй җиткән ләбаса. Нәкъ менә шушы җыр сиңа гомер буе юл күрсәтеп барган шикелле. Халыкның рухы музыкада яши.

Миңа гармун, гармун җитми читтә,
Юлларыма ятар таң нуры,
Яңгырасын иде Европаның
Уртасында татар гармуны.

Яңгырасын иде бер минутка
Европада «Арча», «Сарман»нар,
Түзмәс, торыр татар егетләре,
Сугышларда башын салганнар.

Түзмәс, торыр татар егетләре,
Аларнымы туфрак, кар каплар!
Иярерләр шул гармунга алар
Германия һәм Польша, Карпаттан…

Күргүендә «Кара урман» шаулый,
Юллар авыр, юллар бормалы,
Сикәлтәле, үз язмышы кебек
Бу татарның бөтен моңнары.

Азат итә, сугыша, һәлак була
Батырларча типкән мең йөрәк;
Үлгәннәр дә шул гармунны сагына,
Үлгәннәргә дә моң кирәк.

*С.Хәким, 1970*

Татар дини фикеренең сәясәт белән тәмамланачагы котылгысыз булган, чөнки милли үсешнең күпчелек проблемалары хокукларны киңәйтүгә, дәүләтчелекне торгызуга килеп терәлгән. Бөтен әдәбият шушы фикерләр белән тулган. Тукай иҗаты — аның замандашларыныкы кебек үк сәяси азатлыкка өндәгән җан авазы. Тукайда лирика аз, аның төп аһәңнәре халык язмышына бәйле.

Тукай Пушкинга ачыктан-ачык охшатып, Пушкин шигырьләре үрнәгендә язган, ә кайвакыт аларны тәрҗемә генә иткән. Балалар өчен әкиятләрне Пушкин әкиятләре рәвешендә иҗат иткән. Тукай нәкъ Пушкин кебек үк искиткеч милли. Бу — тирән мәгънәле мисал. Тукай охшатып язуның яки алынма әсәрләрнең халыкның үзенчәлекле сыйфатларына зыян китермәвен раслаган. Бүтән яктан караганда исә этник билгеләрне саклау архаизмнарга берегү дигән сүз түгел. Хәзерге заман кадимчеләренә яхшы җавап бу. Халыкны артка — урта гасыр мәзһәбләренә түгел, бары тик алга барып кына саклап калу мөмкин.

Тукай, әлбәттә, мөселман булган. Ул — муллалар нәселеннән, кая барса да руханилар янында яшәгән, алар белән аралашырга яраткан. Шул ук вакытта ишаннарны, муллаларны, шәехләрне аның кебек тәнкыйтьләгән кешене табу кыен.

Таркатучы милләтне ишан икәндер, белмәдем;
Ул ишаннар милләткә дошман икәндер, белмәдем.

Милләтне бетерүчеләр нәкъ менә шулар икән;
Аларны кире кагучы — намуслы икәндер, белмәдем.

Бу ишанлыклар-фәләннәр бер мәҗүсилек икән,
Нигезе-асылы төпсез бернәрсә икәндер, белмәдем.

Үземне суфи исәпләп, оҗмахны искә ала идем;
Чынында кадерем эт белән бер икәндер, белмәдем.

Шул ук 1906 елда ул Пушкинга багышланган күтәренке рухлы шигырь яза.

Тиңдәшсез шагыйрь булдың, афәрин, Пушкин Александр,
Минем дәртем, омтылышым да синең дәртең белән бер үктер.

...Минем теләгем, максатым — синең тезмә һәм чәчмәләрең;
Мәзһәбеңне һәм динеңне тикшерү минем эшеммени!

Ул механик рәвештә Коръән ятлатып яшьләрне харап итә торган мәдрәсәләрне тәнкыйть итә. Тукай шигырендә шәкертләр үз укуларын болай шәрехлиләр:

Әхлак, вөҗдан,
Инсафларны
Сөреп чыгар-
дык истән дә;

Бозылдык шул-
кадәр начар,
Уздырдык без

Иблистән дә.

Аның мондый шигырьләре, рондо шикелле, якынча шул ук стильдә һәм шул ук эчтәлектә елдан-ел кабатланалар.

Дуслар, тугры юлдан китик,
Ишаннарга һөҗүм итик,
Тозакларын вәйран итик:
Тагы бер кәррә кормасын!

Үзенең үләсен белгән Тукай, вафаты алдыннан, бу темага кабат әйләнеп кайткан һәм элеккеге дәрт белән дингә каршы шигырьләр язган. Сүз ислам турында түгел, бары тик руханилар турында гына, әлбәттә. Бу — Европада реформация башланганда Лютерда, Кальвинда барлыкка килгән антиклерикаль аһәңнәр. Тукайның «исламга каршы» шигырьләре — саф милли тормышка күчү билгесе. Тукай бусага билгеләп куйган, бу бусагадан соң ислам монополия булудан туктаган һәм иҗтимагый тормышның күп институтларыннан берсенә әверелгән. Татарларда исламга гына кайтып калмаган заманча милли аң формалашуга барысыннан да ныграк Тукай ярдәм иткән. Аның тәкъдир ителерлек хезмәте нәкъ менә шунда, ул милли үсешне Европа юнәлешенә борып җибәргән.

Тукай чорындагы әдәбият асылда реформачыл булган, ул прогрессны юл күрсәтүче төп йолдыз итеп куйган, шуңа күрә дә үз әһәмиятен бүгенгәчә саклаган. Аннары «революцион» әдәбият чираты җиткән, ул демократиягә һәм үз дәүләтчелеген торгызуга ышаныч белән сугарылган. Сугыштан соңгы еллар каршы тору этабына әверелгән. Әдәбият телне, мәдәниятне, милли үзенчәлекләрне саклаган һәм бу юлда зур уңышларга ирешкән. Хәсән Туфан һәм Әмирхан Еники — ул чорның иң югары баскычлары. Бүген татар әдәбияты кризис кичерә. Язучылар кыйблаларын җуйдылар. Алар демократия шартларына, цензурасыз һәм контрольсез иҗатка әзер булмаганнарын күрсәттеләр. Алар сүз ирегенә дә, иҗтимагый иреккә дә әзер түгел.

Ислам реформалары ярдәмендә XX гасыр башында татарда алга киткән сәяси һәм интеллектуаль югары катлам оешкан, татарлар икътисад ягыннан нык сәүдәгәрлеккә һәм җитди сәнәгать капиталына ия булганнар. Дәүләт Думасында күренекле татар сәяси эшлеклесе Садри Максуди җитәкчелегендә көчле мөселман фракциясе барлыкка килгән. 1918 елда, татарлар «Идел-Урал» дигән үз дәүләтләрен оештыру турында игълан иткәндә, моның өчен зарури икътисади, сәяси һәм рухи шартлар өлгереп җиткән. Ул заманда татар тормышы дини кысалардан чыккан. Шул ук вакытта җәдидчелек дини тормышны дөньяви яшәеш белән бәйләргә мөмкинлек биргән. Җәдидчелек аларны Төркиядәге кебек капма-каршы куймаган, Төркиядә империячел үткәннән баш тарту исламны үзгәртү аша түгел, ә исламга каршы көрәш аркылы барган.

Ант итәмен так һәм җөп белән мин,
Газават вә кылыч, аваз белән,
Ант итәмен таңгы йолдыз белән,
Ант итәмен кичке намаз белән:

Мин ташламам сине, җанкисәгем!
Юккамыни билеңә кул салдым? —
Күзе үткер шымчыны мин хәтта
Алдадым бит... Сине саклап калдым!

Сусап ирен чатнар көннәреңдә
Сугардым бит эссе чүлләреңне...
Минме өйрәтмәдем көчле сүзнең
Зирәкне дә хәтта җиңәрлеген?!

Бичарага һаман мең чара бул,
Ялгансыз син яшә безнең көндә.
Курыкма! Һәм минем инанганны
Җиткер һәрбер тере шөбһәлегә.

*А.С. Пушкин*
*«Подражание Корану», 1824*
*Зөлфәт тәрҗемәсе*

Дини эзләнүләр белән беррәттән татар тирәлегендә көчле сәяси фикер туган: Йосыф Акчура, Садри Максуди, Гаяз Исхакый... Әлеге искиткеч төркемне Солтангалиев тәгәлләгән.

Йосыф Акчураның 1904 елда Сембер губерниясенең Зия авылында язылган «Сәясәтнең өч төре» дигән зур булмаган хезмәте төрки дөньяның үсеш юллары мәсьәләсен куйган. Төп темасы Госман империясе язмышы булса да, мәкалә бүтән юл сайлау рәвешендә яңгыраган — исламчылыкмы яки төркичелекме? Төркичелек юлы барлык төркиләргә дә кагылган.

Төркичелекне тәгълимат буларак татарлар уйлап чыгарган. Төрки булмаган халыкларның һәм христианнарның проблемаларын хәл итә барып, үзләренең бөек дәүләтен ныгыту юлын тикшерү Госман империясе иҗтимагый фикере өчен табигыйрәк булган. Татарларга исә милли идея якынрак, милли идея — православие империясе шартларында халыкны коткарып калуның табигый юлы. Өстәвенә күпсанлы төрки халыклар арасында яшәгән татарлар өчен гомумтөрки карашларны үстерү дә гаять табигый. Моңа төрки телләр группасында төп тел булган татар теле дә, шулай ук сәүдәне киңәйтү ихтыяҗы да булышлык иткән. Русия хөкүмәте үзе үк татарларны Азия халкы итеп түгел, Русия халкы итеп санап, аларның Русия белән Азия арасында табигый арадашчылар булачакларына исәп тотып дөрес фикер йөрткән һәм Урта Азиягә үтеп керү максатында татарларның Оренбургка күчеп урнашуын хуплаган.

Йосыф Акчура төрки юлны сайлаган, ул ислам ролен инкарь итмәгән, аны икенчел идеология сыйфатында алган. Ул болай дип язган: «Диннәр әкренләп үзләренең әһәмиятләрен һәм көчләрен югалта баралар. Алар үз эшчәнлекләрен иҗтимагый даирәдән кешенең шәхси тормышына күчерә баралар. Намус иреге җәмгыятьтә элек бөтен кешене берләштерүче дин урынын ала башлый. Диннәр, иҗтимагый функцияләрдән баш тартып, кеше җаннарына хак юл күрсәтү белән шөгыльләнәләр, Тәңре һәм ул яраткан затлар арасында намуслы арадашчы булып кына калалар. Нәтиҗәдә диннәр үзләренең сәяси һәм иҗтимагый әһәмиятен этнослар белән берләшеп, аларга ярдәм итеп, хәтта хезмәт итеп кенә саклап кала алачаклар». Акчура ислам вазифалары үзгәрешенең төп юнәлешен дөрес тотып алган. Шуннан бирле тормыш Акчура фикеренең дөреслеген раслап кына тора. Хәзерге заманның дөньяви институтлары эшчәнлеге милләт үсеше өчен дингә караганда файдалырак.

1917 елгы революция башлангач, Русияне үзгәртеп коруның төрле проектлары барлыкка килгән. Нәкъ менә шул чакта Садри Максуди белән Гаяз Исхакый «Идел-Урал» штаты төзүне тәкъдим иткәннәр. Бу идея эшләнеше ягыннан шулкадәр тирән ки, ул хәтта бүген дә кызыксыну тудыра. Ул Русиядә дәүләт төзелешенең федератив принцибына ярашлы булган һәм этник факторга басым ясамаган. Штатны оештыручылар Совет властена лояль, әмма ләкин коммунистлар түгел. Большевиклар штатны игълан итүгә юл куя алмаганнар һәм аны булдырмау максатында татар дөньясындагы каршылыклардан файдаланганнар. Вахитов һәм Солтангалиев бүтән идея — «Татар-башкорт республикасы» төзүне тәкъдим иткәннәр. Асылда исә бу шул ук «Идел-Урал» концепциясе, бары тик социализм идеологиясе нигезендә генә. Әмма большевикларга бу вариант та ярамаган, һәм алар «башкорт карта»сын бик оста уйнатканнар: Зәки Вәлиди белән мөстәкыйль «Башкорт автономиясе» төзү турында шартнамәгә кул куйганнар. Татар-башкорт фронты, тарих мәйданына агрессив большевизмны үткәреп җибәргән дә таркалган. Садри Максуди да, Гаяз Исхакый да, Зәки Вәлиди дә ахыр чиктә Төркиягә барып чыкканнар. Йосыф Акчура Ататөрекнең киңәшчесе булган. Садри Максуди төрки хокуклар тәгълиматын эшләгән, ә Зәки Вәлиди төрки-татар тарихын язган. Гаяз Исхакый төрле илләрдә большевикларга каршы көчләрне берләштерергә тырышкан.

Бу сәяси вакыйгалар Солтангалиев өчен — шәхси фаҗига, ә татар халкы өчен бәхетсезлек булган. Татарлар бердәм булса, татар-башкорт берлеге таркатылмаган очракта илнең тарихы бөтенләй башка булыр иде. Солтангалиевне большевиклар ягында булганы өчен гаепләргә ярамый, чөнки ул заманда социал-демократлар дөньядагы һәм Русиядәге халыклар хокукын, милләтләрнең үзбилгеләнүен яклап чыкканнар. Ул чакта бу өндәмәләрнең гамәлгә ашырылуына шикләнер өчен нигез булмаган әле. Өстәвенә акгвардиячеләр монархияне тергезергә өндәгәннәр, урыс булмаган халыклар өчен моның нәтиҗәсе билгеле. Бакунин кебек алдан күрүчән, зирәк кеше генә социалистик дәүләт барлыкка килүдән күпкә алдан аның бозыклыгын әйтеп бирә алган.

Солтангалиев гадәти большевик түгел, хәтта бөтенләй большевик булмаган дип әйтергә дә мөмкин, гәрчә партиядә торып Милли мәсьәләләр буенча халык комиссариатында эшләсә дә. Ул социализмны исламга бәйләргә, Төркестанда параллель коммунистик партияләр оештырырга тырышкан, колонияләргә каршы совет сәясәтен эшләгән — Ленин Солтангалиев фикерләрен генә сөйләп йөргән. Солтангалиевнең большевикларның Көнчыгыш сәясәтенә йогынтысы хәтта аны 1923 елда кулга алгач та сизелеп торган. Солтангалиевнең «ислам социализмы» тәгълиматы татарларның реформа чорын гаҗәеп төстә тәмамлап куя.

Социализм идеяләре XX гасыр башында бөтен Европа фикеренә тәэсир иткән, ул чакта коммунистик «экспериментлар»ның нәтиҗәләре турында уйлаган кеше сирәк булган. Капитализм искергән, кешелексез юнәлеш булып күренгән, ә социализм исә баштан ук үз концепциясенең үзәге итеп гуманизм идеяләрен алган. Бары тик XX гасыр ахырына гына капитализм, коммунистик юлдан сабак алып, социалистик идеялә-

нең күпчелеген үз системасына кертте. Капитализм тышкы басым астында кешелекле системага әверелгән, ә коммунизм исә, киресенчә, дәүләтсез җәмгыять идеясеннән кешелек тарихындагы иң тоталитар дәүләтчелеккә әверелгән. Шаккаткыч әверелешләр — капитализмныкы да, социализмныкы да.

Солтангалиев ислам кыйммәтләрен социализм идеяләре белән берләштергән, бу исә гарәп илләрендә яңгыраш тапкан. Александр Беннигсен аны тикмәгә генә «өченче дөнья» идеологы дип атамаган. Ахыр килеп, Солтангалиев 1929 елда төрмәдә утырганда Советлар Союзының таркалачагын әйткән. Татарларның мөстәкыйль иҗтимагый фикере Солтангалиев белән төгәлләнә. Татар галимнәренең эмиграциядә язган хезмәтләре Русиядә башлаган эшләренең дәвамы гына булган һәм күбрәк татарның үз проблемаларына түгел, ә гомумтөрки темаларга кагылган.

Социализм вакыйгаларның табигый агышын туктаткан. Русия җәмгыяте яңа әверелеш чорына кергән: агрессив атеизм белән коралланып, исламны да, православиене дә кире каккан. Шул рәвешле исламның менә дигән үзгәртү идеяләре канга тончыгып юкка чыккан.

Җир шул килеш... Күк гөмбәзе —
Җиһан Синең җилкәңдә,
Йолып кала күр, Ходаем,
Гарасатлар үткәндә.

Җиһанга кояш кабыздың,
Яктыңны бирдең инде —
Дөнья тирәгеннән һаман
Хуш ис аңкыса иде!

Табынабыз: «Аллаһ бөек,
Дөнья Аның иркендә,
Теләсә ул шау яңгырны
Яудыра эссе көндә.

Шәфкать кылып, Мөхәммәдкә
Ачты ул Коръән серен...
Хәер, җиргә төшик... Аның
Күтәрик пәрдәләрен!»

*А.С. Пушкин*
*«Подражание Корану», 1824*
*Зөлфәт тәрҗемәсе*

Татар ислам реформасы җәмгыятьнең, гомумән, бөтен дөньяда бара торган либеральләшү процессының бер өлеше булып торган. Бу күзлектән караганда, ул төгәлләнергә тиеш. Безнең көннәрдә җәдидчелек котылгысыз рәвештә яңа рәвеш алачак, чөнки тормыш шартлары үзгәрде. Бүген татарларның үз дөньяви уку йортлары, шул исәптән университетлары да, Татарстан Республикасы рәвешендә, тулы кыйммәтле үк булмаса да, үз дәүләтчелеге дә бар. Демократия күпчелек иҗтимагый институтларны мәдәниятне үстерү максатында файдаланырга мөмкинлек бирә, гаммәви мәгълүмат чараларының йогынтысы мәчетләрнекеннән көчлерәк. Татарларның тормышы нигездә дөньявига әйләнде. Икътисади үсешен фәнни тикшеренүләр, югары технологияләр билгели торган теләсә кайсы җәмгыять исламга реформа ясау юлыннан барачак. Җәдидчелек татарларга гына хас үзенчәлек түгел, ул — ислам дөньясына Ходай язган юл. Вазгыять шулай килеп чыккан: әлеге тарихи инициативаны беренче булып татарлар үз кулларына алганнар.

Авиация, автомобиль, суднолар төзү, электроника һәм икътисадның башка югары технологияле тармакларына ия була торып та мондый җитештерүгә ия булмаган Көнчыгышта калу мөмкин түгел. Ислам дөньясында өйрәнерлек нәрсә юк. Ислам дөньясында әхлакның югары булуы турында тезис та ачык түгел. Анда эчкечелек һәм фахишәлек кебек бозыклыклар юк югын, әмма әхлакый прогресс бармы соң? Шикле. Ислам илләренең байлыклары нигездә хезмәт нәтиҗәсе белән түгел, нефть запаслары белән билгеләнә. Тормышның чагыштырмача югары дәрәҗәсе дә нефтькә бәйле. Нефтьне тартып алсаң, алар бик кызганыч хәлдә калырлар иде. Бай ислам илләрендә эш эзләп килгән иммигрантлар күп бүген. Эшләүчеләр дә нәкъ менә шулар, ә гражданнар үзләре нефть запаслары биргән өстенлекләрдән файдаланып идарә итүче катлау ролен башкаралар. Әлеге югары катлау төп нефть долларларын ислам банкларына түгел, Америка һәм Көнбатыш Европа банкларына урнаштырып бу акчалардан процент алып ята, ә бит шәригать моны тыя. Алар рантьелар  кебек яшиләр. Бу — шикле әхлак һәм шикле киләчәк. Һәрхәлдә, мондый илләр, үзләрен исламны саклаучылар дип атасалар да, үрнәк булып тора алмыйлар. Татарстан ул илләрдә үз тауарларын сата ала, конкурентлыкка сәләтле булган очракта, әлбәттә. Әмма Татарстан алардан өйрәнә алмый. Чөнки анда өйрәнерлек нәрсә күренми.

Дөнья икътисадындагы интеграция процессы төп өч куәтле сәүдә үзәге тирәсендә кайный. Төньяк һәм Латин Америкасы гомумсәүдә зонасына берләшү процессын тәмамлап киләләр. Берләштерелгән Европа — инде гамәлгә ашкан факт, аның хәтта үз валютасы да бар. Азия-Тын океан төбәге үз сәүдә зонасын Япония, Кытай, Корея, Тайвань, Сингапур тирәсендә оештыра, бирегә хәтта Индия, Австралия һәм Яңа Зеландия дә керә. Җир шарының киләчәген өч уенчы билгеләячәк — берләштерелгән Америка, берләштерелгән Европа һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия. Сүз уңаеннан, Ислам дөньясы, Русия кебек үк, бу процесстан төшеп калды. Ислам дөньясын интеграция кызыксындырмый, анда рантье психологиясе инде тамыр җәйгән, аңа Көнчыгыш банкларындагы акчасын саклап калу мөһимрәк.

Гомумән алганда, Русия алдында ике юл бар: БДБ илләренең кайберләре белән Евразия берлеге төзү яки Европага кушылу. Беренче юл абруйлырак һәм табигый диярлек. Ләкин мондый берлеккә керергә теләүче илләр күп булмас. Бу, нигездә, Казахстан, Кыргызстан, Белоруссия, Таҗикстан. Бу исемлеккә әллә ни ис китми. Һәрхәлдә, Русия өчен бу алга түгел, артка таба адым ясау. Татарлар һәм Татарстан өчен мондый берлек отышлы, чөнки сату базары киңәя, ул илләрдә татарлар күпләп яши. Ләкин Евразиянең мөстәкыйль берлек буларак киләчәге юк. Анда таянырлык көчле идея күренми. Димәк, маяк булып — белем һәм технологияләр, сәяси һәм икътисади тормыш стандартлары чыганагы булып Европа кала.

Урыс культурасы, ниндидер мөстәкыйль Евразия цивилизациясе итеп нигезләргә тырышуларга карамастан, асылда — европачыл культура. Тик соңгы гасырда Русия Көнбатыш Европа белән конфликтка керде һәм «Берлин стенасы» нәселдән килгән чир булып чыкты. Чынлыкта исә Русиядә Көнчыгыш культурасыннан берни дә калмаган һәм ул православие нигезендә мөстәкыйль культура да тудыра алмаган. Шуңа күрә бөтен православие дөньясы бер-берсен уздыра-уздыра Европага ыргылган. Русия Европа культурасының читендә калган. Европа культурасын аңлы рәвештә сайлап аласы урынга, ул аның үтеп керүенә карыша, үзе эрзац-культурадан файдалана.

Татарлар өчен тарих сайлау мөмкинлеге калдырмаган. Зарыгып көтелгән, омтылган максат сыйфатында бары тик Европа гына каралырга мөмкин.

Европа баштан ук протестант-католик культура буларак оешкан, әмма аның идея үзәге — либерализм. «Англиядә сәяси либерализм протестантлар һәм католиклар арасындагы дини сугышны туктаткан, ул сугыш XVII гасырда илне һәлакәткә китерә язган,— дип яза Фрэнсис Фукуяма,— либерализм барлыкка килгәч, дин үзенең чага торган угын югалткан, чөнки үзен сабыррак тота башлаган». Либерализм — универсаль идея, кыйммәтләрнең шундый ук универсаль системасын кешелек дөньясы хәзергә эшләп чыгармаган әле. Либерализмны алмаштырырлык идея юк. Европа чикләрен нәкъ менә либерализмның таралу колачы билгеләячәк. Шушы җирлектә ул үз рәтенә Төркияне дә алачак. Ислам киртәсен узып чыгу — вакыт мәсьәләсе генә. Европа православие киртәсен узып чыга алган бит әле. Ахыр чиктә яһүдилекне, христианлыкны, исламны берләштерүче Авраам тамырларын мәдәни нигез итеп алырга мөмкин.

Ләкин яңа «Берлин стенасы» барлыкка килмәсен өчен, ислам үзе дә Европага таба, либерализмга таба барырга тиеш, ягъни ул евроисламга әйләнергә тиеш. Җәдидчелек традицион татар һәм ислам кыйммәтләрен либерализм һәм демократия идеяләренә табигый бәйләргә мөмкинлек бирә. Җәдидчелекнең мөстәкыйль тәнкыйди алымы (иҗтиһад) либераль фикер йөртү булып тора да инде.

«Тергезү» термины урысча да, татарча да еш кулланыла, әмма ул хәзерге заман мәсьәләләренең асылын аңлатмый, тик томалап кына тора. урыслар өчен тергезү православиегә һәм державачылыкка кайтуны аңлатырга мөмкин, әмма болар берсе дә ил үсешенең стратегик юнәлеше була алмый. Татарлар өчен тергезү бүтәнрәк мәгънәгә ия: тел үсеше, милли мәктәпләрне, мәдәни үзәкләрне тергезү, мәчетләр салу. «Тергезү» термины мәгънәсе буенча — ни урысча, ни татарча — Европача тергезүгә туры килми, Европача тергезү культураны урта гасырлар кысасыннан чыгарган. «Тергезү» терминын Русиягә кагылышлы рәвештә куллану мәгънәсез, хәер, аны татар тирәлегендә куллануның да зарурлыгы юк, чөнки культура инфраструктураларын тергезү чоры инде тәмамлана һәм алдыбызга ыргылыш рәвешендәге бурычлар куярга кирәк. Үткән заманны әкиятләштерүнең хаҗәте юк. Үткәннәр үткәндә калсын. Бернәрсәне дә тергезергә кирәкми, чөнки заманча шәрехләүдә «тергезү» артка сөйри.

Иске мәзһәбләр инде тарих булып калды. Бүген мәзһәбләрне яклаучы кешеләр урта гасырларда яшиләр яки мәзһәб кагыйдәләрен саклаган булып кыланалар. Алар хәйләлиләр, дөньяви дәүләттә шәригать законнары буенча яшәү мөмкин түгел. Әгәр дә син кануни мәзһәбне эзлекле рәвештә яклыйсың икән, димәк, син ислам дәүләте төзү максаты куярга тиеш, мәзһәбне башкача гамәлләштерү мөмкин түгел. Ачык ки, Русиядә мондый бурыч куюның мәгънәсе дә, кирәге дә юк. Әйтик, дөньяви дәүләттә күп хатынлылыкны ничек тормышка ашырып була? Бу дәүләт күп хатынлылыкны танымый лабаса. Русиянең җинаять кодексына каршы килүче шәригатьне ни рәвешле гамәлләштерү мөмкин? Бөтен дөньяда коллык бетерелгән заманда мөселман кануннары буенча кол кызлар сату һәм алу мәсьәләсен кую кирәк мәллә?! Вакытлар узу белән нормалар үзгәрә, ә хакыйкатьне эзләү ысулы шул ук. Урта гасырларда яшәгән мөселман акыл ияләре әйт-

кәннәр: «Шикләнмә! Хакыйкатьне нәкъ менә шулай табарсың». Хакыйкать ул — Аллаһы Тәгалә үзе. Алга киткән җәмгыятьне традицион җәмгыятьтән үзтәнкыйть аерып тора. Өстәвенә тәнкыйди рух һәм иҗтиһад дини кагыйдәләрне тәңгәлрәк гамәлләштерүгә алып бара. Барлык заманнар өчен дә иң бөек философ Сократ китапларны сөймәгән, чөнки ул «катып калган фикер фикер түгел» дип санаган. Әлбәттә, Платон китаплары булмаса, без Сократ турында белмәс идек. Әмма кешелек барлык гасырларда да Сократ алымына — диалогка әйләнеп кайткан, кара-каршы сөйләшкәндә генә фикер туа. Шуңа күрә университетлар бар, аларда «катып калган» белемне генә түгел, яңа белем эзләүгә алып бара торган тере фикерне дә тапшырып калу өчен профессорлар студентлар белән әңгәмә коралар.

Иң кыю адымнарга барган, хәтта Мисырдан Иранга кадәр көчле революцияләр дулкыны уздырган ислам илләре ни өчен үзгәрә алмаганнар? Алар Көнбатыш тәгълиматларын белгәннәр, тәвәккәл итеп демократиягә йөз тотканнар, фәннәрне үстерергә тырышканнар, техник һәм технологик яңарыш юлына басканнар, ләкин шуңа да карамастан алар Көнбатыш илләрдән бик тиз артка кала баралар. Чөнки мәзһәбләр кысасыннан чыгарга сәләтсез аңнары комачаулый.

Европалылар якынча 500 ел элек Кытайга барып чыкканнар һәм анда үзенчәлекле җәмгыятькә тап булганнар. Анда борынгы галимнәрнең тирән гыйлеме аркасында сәнгать һәм һөнәрләр билгеле бер камиллеккә ирешкән, әмма фән үзе булмаган. Европалылар күз алдына ниндидер сәер рухи торгынлык килеп баскан. Кытайлылар элеккеге цивилизациянең җимешләреннән оста файдаланганнар, ләкин мондый нәтиҗәләргә ирешү ысулларын белмәгәннәр. Алар прогресс идеясеннән читләшкәннәр. Алексис де Токвиль фикере буенча, хакыйкать нурын үз аяклары белән таптаучы халыклар бар. Ислам дөньясы да рухи торгынлыкта.

Һәрбер дин рухи вәхидән башланган, соңыннан институтлар, руханилар барлыкка килгән һәм дин рухиятне түгел, үз катламы мәнфәгатьләрен яклый башлаган. Дин дәүләт оешмаларының төзелешен кабатлый. Без моның иң ачык мисалын иезуитларда күрәбез. Башка дини агымнар, шул исәптән ислам да шул ук юлдан барган, вакыт-вакыт кяферләрне «инандыру» өчен көч тә кулланылган. Рухиятне көч белән яклау мөмкин хәлме? Билгеләмә буенча болар бер-берсенә капма-каршы нәрсәләр. Әмма шулай булган. Дин институтка әйләнгәч, кешеләр арасында дивар барлыкка китергән, чөнки вәхиләрнең соңгы шәрехләре катгый доктрина формасына китерелгән һәм руханилар үз институтларының бар куәтен рухиятне түгел, шул догмаларны яклауга җигәләр. Тарихтан күренгәнчә, руханилар рухиятне нигытудан бигрәк мөртәтләргә каршы көрәшне кайгырткаnнар. Ә бит нәкъ менә мөртәтләргә һәм үзгәрешләргә (бидгать) каршы көрәш иҗади рухны җимерә һәм динне иҗтимагый үсеш юлындагы киртәгә әйләндерә. Джон Стюарт Милль болай дип язган: «Фикер ирекле булмау аркасында кешеләр үзләре таныган хакыйкатьнең нигезен белмиләр, ул гына да түгел, бу хакыйкать алар өчен үз мәгънәсен югалта, аны гәүдәләндерүче сүзләр тора-бара кешеләрдә башта үзләре гәүдәләндергән идеяләрне уятудан туктыйлар яки өлешчә генә кызыксындыра башлыйлар. Тере аң, тере иман югала һәм бөтен хакыйкатьтән гадәти кабатлана торган берничә гыйбарәдән гайре берни дә калмый, калса да — бары тик кабык яисә кибәк кенә кала, ә төш-орлык үзе һәлак була. Бу факт кешелек тарихында бөек әһәмияткә ия». Беренче мөгаллимнәр һәм аларның шәкертләре өчен дин мәгънәдән, тормыштан гыйбарәт. Алардан соңгы буыннар диннең асылын онытканнар, ә руханилар фикер хөрлегенә каршы көрәшкәннәр. Моннан соң дин бары тик тышча гына булып калган, күпчелек йолаларны үтәүгә генә кайтып калган. Дин иҗади процесстан тормышны «туктатып калу» ысулына әйләнгән, ул кешене «табигатебезнең иң югары хасиятләренә мөрәҗәгать итүче барлык тәэсирләрдән саклый, гүя аның бар көче берninди дә тере карашка юл куймаудан тора, ул акыл өчен дә, йөрәк өчен дә үле һәм аларның бушлыгын саклаудан гайре берни дә эшләми». «Хактыр, Аллаһы Тәгалә һәр гасыр башында өммәткә динне яңарту өчен кеше җибәрәчәк»,— дип кисәткәндә Мөхәммәд пәйгамбәр шуны кайгыртмады микән? Ул дин институты өчен түгел, ә кешенең рухияте өчен борчылган. Мөхәммәд пәйгамбәр исән чакта ук Гомәр бин әл-Хаттаб һәм Һашим бин Хәким «Аеручы» сүрәсен кем дөресрәк укый, дип бәхәсләшеп, пәйгамбәр янына килгәннәр. Мөхәммәд пәйгамбәр Һашимнең укуын тыңлаган да әйткән: «Ул миңа шулай иңдерелгән иде!» Аннан соң ул Гомәрне тыңлаган һәм: «Ул миңа шулай иңдерелгән иде! Хактыр, бу Коръән шул рәвешчә иңдерелде ки, аны җиде ысул белән укып була, үзегезгә ничек җиңел, шулай укыгыз»,— дигән. Димәк, ул сүз хәрефе турында түгел, рухият мәгънәсе турында уйлаган.

Дин — оешма эшчәнлек, ә рухият — һәркемнең шәхси эше, һәркемнең Аллаһка мөнәсәбәте, югары кыйммәтләрнең мәгънәсен, аларның фани кыйммәтләрдән өстенлеген аңлавы. Рухият шәхесне билгели. Җәдидчелекнең мәгънәсе мәзһәбтән баш тартып рухияткә кайтудан гыйбарәт. Ул ниндидер бер агымга әйләнмәгән, чөнки үзенең төп сыйфаты итеп даими рухи эзләнүне санаган. Җәдидчелекнең заманча формасы (яңа җәдидчелек) буларак евроисламны яклап, без яңа мәзһәб ясамыйбыз, бары тик реформаларны дәвам итү турында гына сөйлибез.

Коръәндә гомуми принципλар бирелгән, алар төрле дәверләрдә законнар (шәригать), әхлакый нормалар, рухи эзләнүләр рәвешенә керәләр. Бүгенге заман Коръәнне яңадан укып чыгуны таләп итә. Тәнкыйди фикер (иҗтиһад) хәзерге заманда Коръәнне яңа шартларга кагылышлы рәвештә шәрехләүнең төп ысулына әйләнә. Үткән заманның дини тәгълиматларында мәзһәбләрдә ныгытылган нормалар түгел, өйрәнү ысулы төп казаныш булган.

Кагыйдәләр, нигезе кыйммәтләр үз-үзеңне тоту нормаларыннан ни белән аерыла? Үзләренең мәңгелек булулары белән, әмма аларның эчтәлеген аңлау төрле дәверләрдә, төрле шартларда иҗтиһад таләп итә. Гаделлек принцибы мәңгелек. Хикмәт бары тик шунда ки: без, вакытлар узу белән, аңа башка эчтәлек салабыз. Урта гасырларда ир-атның һәм хатын-кызның тигезсезлеге матди һәм башка шартлардан чыгып караганда гадел булган. Бүген исә гаделлек — ир-ат һәм хатын-кызның тигезлеге ул. Урта гасырларда гаделлек табышны бүлешүне күздә тоткан, ә бүген бу турыда сөйләү дә уңайсыз, бу юлбасарлар тәкъдире булып калган. Элек коллык институты булган һәм Коръән аларга игелекле мөнәсәбәт таләп иткән, ә Мөхәммәд пәйгамбәр кешеләрне коллыктан коткаруга өндәгән. Бүген исә коллыкны тану — хурлык. Коръәннең рухы һәм хәрефе бар. Рухы — гаделлек кебек мәңгелек хакыйкатьләрдә, ә хәрефе — урта гасырлар шәрехләвендә, мәзһәбләрдә.

*Бервакыт Хуҗа Насретдингә әйткәннәр:*
*— Синең күршең казый акылдан язган.*
*Хуҗа уйга калган.*
*— Син нишләп болай уйга калдың, Хуҗа?*
*— Минем казый күршем тумыштан ук ахмак бит, ничек акылдан язган икән соң ул? Шуны уйлап торам әле менә,— дигән ул.*

Евроисламның мәгънәсе нидә? Кешелекнең бердәм булуын, гомумән алганда, аның христианлык дөньясына һәм мөселман өммәтенә бүленмәвен аңлауда. Кешелек инде күптән язылган һәм язылмаган гомуми законнар буенча яши, кыйммәтләрнең гомуми системасы эшләнгән, аның нигезендә Ибраһим (Авраам) кагыйдәләре ята. Халыкара хокук тормышның күп даирәләрен җайга сала, ә халыкара институтлар аларның үтәлешен тикшерәләр. Бөтен дөнья өммәткә әйләнде.

Евроислам — тәнкыйди, рациональ фикер, Ходай рәхмәтенең абсолютлыгын аңлау нигезендә диннәргә тигез караш. Ул җиһадны кяферләр белән сугыш дип түгел, аның югары мәгънәсендә — үз-үзеңдәге шикләргә каршы көрәш дип шәрехли, ир-ат белән хатын-кызның тигезлеген таный, рухи башлангыч өчен фани дөнья белән нәфескә каршы көрәш алып бара, чын дини кешенең беренче бурычы итеп белемгә һәм фәннәр белән шөгыльләнүгә омтылышны куя.

Евроислам — рухияткә кайту ул. Бу «алтын бозау» артыннан чаба-чаба үз дини эзләнүләренең күбесен онытып җибәргән Европага да рухият кертү дигәнне аңлата. Христианлык Алласын акча Алласы алмаштырды.

Европада Реформация сәяси һәм, гомумән, иҗтимагый тормышны чиркәү йогынтысыннан азат иткән, бу исә сәяси системаны яңартырга мөмкинлек биргән. Бүгенге Көнбатыш нәкъ менә шушы формула аркасында алга киткән. Ләкин рухият югалган, аны матди байлык артыннан куу алмаштырган. Хәер, рухи бушлык сәнгать, нәфис әдәбият белән тутырыла, алар кайчандыр дин үтәгән вазифаны үзләренә алалар.

Оешкан диннәр үзләренең бүгенге рәвешләрендә проблемаларны хәл итү юлы түгелләр, алар үзләре үк шул проблемаларның берсе. Мәзһәбләр исә татарларга алга таба үсеш юллары күрсәтмиләр, иң уңай очракта — алар артка калганлыкны «катырып» куялар, ә иң тискәресендә — урта гасырлар тупигына кертәләр, рухиятне суррогатка алмаштыралар. Мөхәммәд пәйгамбәр болай дип киңәш иткән: «Кем дә булса башкаларны өйрәтү максатында күпме булса да фән өйрәнсә — аңа Аллаһы Тәгалә җитмеш изгенең котылу чарасын бирер». Башта мөселманнар бу киңәшләрне тотканнар, алар рухиятне эзләү белән мәшгуль булганнар һәм башкаларны өйрәтергә омтылганнар. Шуңа күрә урта гасырларда бөтен фәннәр мөселман университетларыннан чыккан.

Бүген татарларда дини фикер юк диярлек, ул совет чоры тарафыннан шулкадәр бозылган ки, ислам бары тик примитив йолаларга гына кайтып калган. Бу турыда язу аяныч, чөнки революциягә кадәр татар дини тәгълиматы ислам дөньясында иң алдынгы тәгълимат булган. Ул чорда җәдидчеләрнең колачына, тирәнлегенә һәм алдан күрүчәнлегенә беркем дә тиңләшә алмаган. Бүген дөньяда бу мирастан күпләр файдалана, тик безнең имамнар гына, тиешенчә уйлап җиткермәстән, аннан йөз чөерәләр.

Тарих үткән юлга әйләнеп карап, яңа заманда татарларның дөнья культурасына керткән өлешен бәяләп карасак, без җәдидчелектән гайре берни дә атый алмыйбыз. Хәер, без бөек дип атый торган Тукай бар, Дәрдмәнд бар. Алар чыннан да бөек, ләкин безнең өчен генә. Аларны башка халыклар бәяли алмый, алар,

мәсәлән, Пушкин кебек, милли миссия үтәгәннәр. Пушкин да Европага шулай ук аз мәгълүм. Без Фәрит Яруллин белән горурланабыз, ләкин ул Чайковский яки Мусоргский кебек колачка ирешә алмаган, ул иртә үлгән. Татарлар, ислам дини тәгълиматында ыргылыш ясап, кешеләргә рухиятне кайтарып дөнья культурасына гамәли өлеш керткәннәр. Аның асылын ислам дөньясы әле ахыргача аңлап җиткермәгән, бередә совет чоры йогынтысы сизелә. Татар дин тәгълиматчыларын дөнья таный башлаганда, СССРда инде мөселманнарны эзәрлекләгәннәр, һәм җәдидчеләр мәктәбе эше өзелеп калган.

Бу тормышта теге яки бу вакыйганы, илнең киләчәген, хәтта үз язмышыңны да алдан белү мөмкин түгел, ләкин алдан әйтеп була торган бердәнбер факт бар — үлем ул. Шуңа карамастан без аны әле тиз генә булмас дип ышанып яшибез. Матди байлык артыннан чабабыз, гүя тормышның мәгънәсе яки кеше бәхете шул байлыкта. Ата-аналарыбызның, ата-бабаларыбызның портретларын караганда, без аларның нинди машинада йөргәнен искә төшермибез. Теләсә нинди «Мерседес» бик тиз бер күч тимер-томырга әверелә һәм шушы салкын тимергә кемнең һәм күпме күңел көче кергәнлегенә киная ясап тора. Без ата-аналарыбызның рухияте белән горурланабыз. Үз милләтебезнең рухияте белән горурланабыз. Игътибар итсәгез, бер генә халык та үзе саткан нефть күләме белән горурланмый. Заманында Германиянең яки Англиянең дөнья базарына күмер кертүче төп илләр булганлыгын кем дә булса хәтерли микән? Ихтимал, моны махсус белгечлектәге тарихчылар беләдер. Кешеләргә исә Гете һәм Шекспир мәгълүм. Ахыр чиктә дөньяны халкының дөнья культурасына керткән өлеше, рухи эзләнүләреңнең кабатланмас үзенчәлеге кызыксындыра. Дөнья Рудольф Нуриевка, Софья Гобәйдуллинага, Николай Лобачевскийга, Федор Шаляпинга соклана. Шәһәреңне, халкыңны һәм мәдәниятеңне алар исеме буенча беләләр.

Кешелек мәзһәбләргә түгел, рухияткә мохтаҗ. Кемдер рухиятне эзләп мистикага кереп китә, Һиндстанга, Тибетка бара, иң хируслары шаманлык белән мавыга. Аларга үпкә белдерергә яисә хөкем чыгарырга ярамый, алар соңгы меңьеллыкта диннәр югалткан нәрсәләрне эзлиләр. Зыялылар бу миссияне үзләренә алырга тырышалар. Лев Аннинский әйтүенчә, «чынлыкта исә элек Чиркәү башкарган эшне хәзер без башкарырга тиеш».

Җәдидчеләр исламга рухиятне кайтарырга омтылып караганнар. Бу — ике йөз ел элек ислам үзгәрешен билгеләгән бөек омтылыш. Аны дәвам итү бездән тора.

Кешеләрнең күпчелеге, җәмгыять, дәүләт, милләт миңа нәрсә бирә ала дигән сорауга җавап эзли, бары тик бик аз кеше генә башкача фикер йөртә: «Бу дөньяга мин нәрсә бирә алам?» Менә шундыйларның исемнәре тарихта кала.

## Сөйкемле «Мәңгелек Төрки ил»

*Төн утырмыйча, көндез йокламыйча, кызыл каным түгеп, кара тиремне йөгертеп, акылымны-көчемне бирдем. Шулай ук ерак яуларга йөрдем... Илтериш каган каганлыкны ныгытмаса, аңа ияреп мин үзем каганлыкны ныгытмасам, илем дә, халкым да юкка чыгачак иде. Казануым, тырышлыгым аркасында, ияртә алуым аркасында ирешелгәннәрем, казанган уңышларым өчен илебез көчле ил булды, халкым көчле халык булды. Үзем картайдым, дәрәҗәле булдым. Әгәр берәр җирдәге каганлы халыкның ахмак идарәчеләре булса, нинди борчуларга дучар булырлар иде.*

Төньйокук истәлеге. 726

Яңа дәвер чигендә Азия вакыт-вакыт кеше энергиясе куерлыгы тудырган. Ул вулкан кебек кайнап торган, әле һуннарны, әле төркиләрне, әле кыпчакларны, әле татар-монголларны өскә чыгарып аткан. Бу халыклар Көнбатышка юл тотканнар, аннан соң кире кайтканнар, бетмәс-төкәнмәс ташкын булып янә һөҗүм иткәннәр һәм үзләре туктаган һәрбер җирдә дәүләтләр төзегәннәр. Төркиләр һәрвакыт дәүләтчеләр булганнар һәм хәзергәчә шулай.

Каганлык оештырганчы «төрки» термины башта — 10, соңрак 12 кабилә берлеген — «төрки бодын»ны аңлаткан. Ә дәүләт исә «Төрки ил» дип аталган. «Ил» империя яки держава дигәнне аңлаткан. Беренче төрки каган Бумын жужаннарны буйсындыргач, «Ил хан» титулын алган. Шуңа күрә «ил» төшенчәсе кабилә үзидарәсен түгел, ә башка илләрне буйсындыруны чагылдырган. Соңрак «ил» сүзе ил, дәүләт дигәнне аңлата башлаган.

Мин — язмышлар язам,
кара атта барам!
Сынган җиреңне — ялгыйм!
Өзелгән җиреңне — бәйлим!
Мин — ил төзим!
Ил имин-бәрәкәтле булсын!

*«Фал китабы». X гасыр*

Төркиләр дәүләт төзергә маһир булганнар. Азиядә һәм Көнчыгыш Европада һуннар империясе җимерелгәч, 551 елда Беренче Төрки каганлык барлыкка килгән. 558 елда төркиләр Идел һәм Урал буйларын буйсындыруны төгәлләгәннәр. Иң зур биләмәләргә ия булган мәлдә Төрки каганлык Маньчжуриядән Киммерий Боспорына (Керчь бугазына) кадәр, Енисейның үрге агымыннан Амударьяның үрге агымына кадәр җәелгән. Моңа үсеш дәрәҗәсе буенча башка барлык күчмә халыклардан өстен, камил гаскәр һәм идарә системасы аркасында ирешелгән.

Бумын каган династиясенең башкаласы Өтүкән тавы һәм Урхун елгасы арасында урнашкан. Соңыннан аны Каракорым дип атаганнар һәм ул Монгол империясенең башкаласы булган.

731 елда Күлтәгин вафат булгач, аны күмәргә дөньяның күп илләреннән илчеләр килә, бу хакта борынгы ташка болай дип язылган: «Елаучы, сыктаучылар кытан, татабы халкы Удар Сәңүн җитәкчелегендә килде. Табгач (кытайларның борынгы атамасы) каганлыгыннан Исьи Ликәң килде: бер мең алтын, көмеш, байлык — хисапсыз бүләкләр бирде. Тибет каганлыгыннан Бөлөн килде. Көнбатыштан Согд, Бәрчәкәр (фарсы халкы), Букарак (Бохара) улусы халыклары килде. Нәң Сәңүн, угыл Таркан килделәр. Ун ук (көнбатыш төрки угызларның ун кабиләсе) халкы, улым Түргиш каганы исеменнән Макрач тамгачы, Үгез Билгә тамгачы килделәр. Кыргыз каганлыгыннан Ынанчу Чур тардуш килде. Төрбә төзүчеләр, осталар, бизәк төшерүчеләр, ташка уеп язучылар — барысын Табгач каганы Чәң Сәңүн алып килде... Бу кадәр күп осталарны тойгун һәм әлтабарлар китертте». Ташка уелган әлеге язма Беренче Төрки каганлык урнаштырган халыкара мөнәсәбәтләрнең никадәр киң колачлы икәнен күрсәтеп тора. Башка бер каганның җеназасында Византия илчеләре дә булган.

Һәйкәлләрдә төрле язмалар булу үзе үк төркиләрнең халык алдында әйтелгән сүзне гамәлдәге көч итеп санаулары турында сөйли, инде шул заманда ук иҗтимагый фикер дигән төшенчә яшәгән.

Төркиләр экспансиясенең үз дәүләт идеологиясе булган, ул менә мондый кыска формулада чагыла: «Безнең коллар — колбиләүчеләр, ә кол хатын-кызларыбыз колбиләүче хатын-кызлар булдылар». Төп чара — көч булган. Ул гаделлек белән әллә ни яраша алмаган. Халыкларны һәм илләрне буйсындыра-буйсындыра алар үзләре хәлсезләнгәннәр һәм үзләренең кул астындагы халыкларны Кытай империясе белән берлеккә этәргәннәр, һәм бу ахыр чиктә каганлыкны һәлакәткә китергән дә.

603 елдан каганлык Көнчыгыш төрки һәм Көнбатыш төрки өлешләргә аерылган. Көнчыгышта күчмә халык яшәсә, көнбатышта халыкның күпчелеге утрак булган һәм җир сөрү, һөнәрчелек, сәүдә белән шөгыльләнгән. Озакка сузылган нәселара көрәштән (640 — 657) кытайлар файдаланган. Нәтиҗәдә, соңгы төрки хаким 659 елда әсирлектә үлгән.

Төркиләрнең бәйсезлек өчен көрәше башланган (679 — 689). Көнчыгыш төрки каганлыгын торгызуны үзенең иң якын киңәшчесе Тоньйокук белән Илтериш каган исеме алган Котлуг башлаган. Тоньйокук үзләренең хәрби походларын ташка уеп болай тасвирлый: «Гаскәрем белән яуга киттем. Алтун ешлыгын юлсыз уза алдым. Иртыш елгасын да күперсез кичә алдык, төн буе бардык, таң беленгәндә Болчуга җиттек. «Тел» тотып кайттылар, сүзе шул булды: «Ярыш даласында ун мең гаскәр җыелды»,— диде. Ул сүзне ишетеп, бәкләр барысы: «Кайтыйк, яхшыларга ояты кыйммәт, ә җиңелү — зур оят»,— диделәр. Мин болай дидем: «Мин билгә Тоньйокук! Алтун ешлыгын узып килә алдык, Иртыш елгасын кичеп чыга алдык. Килгәннәр — барысы батырлар! — дидем.— Безнең монда икәнлекне дошман белми. Тәңре, Умай, изге җирсу — барысы безне саклый, безгә җиңү бирә, нигә качарга? Алар күп дип нигә куркырга, без аз дип курыкмыйк. Нигә безгә җиңелергә? Аларга һөҗүм итик»,— дидем. Яуга ташландык, дошманны таркаттык. Икенче көн тупланып тагы килделәр, уттай кызып килделәр. Сугыштык. Алар бездән ике канатка күбрәк иде. Тәңре ярлыкаганы өчен алар күп дип курыкмадык, сугыштык. Тардуш шад та безнең арада сугышты. Дошман гаскәрен таркаттык, каганын тоттык. Ябгусын (хәрби чин), шадын (каган ярдәмчесе) шунда үтердек. Иллеләп сугышчыларын кулга алдык. Шул ук төнне халыклар саен илчеләр җибәрдек. Ул сүзләрне ишетеп, Ун ук бәкләре күпләп килделәр, буйсындылар. Килгән бәкләр халкын урнаштырдым, халыкның бер өлеше аерылып китте. Ун ук гаскәре белән сугышка чыктык. Без тагын сугыша башладык, дошманнарны кудык...» Көнчыгыш каганлык шулай торгызылган.

Аннан соң 699 елда төргәшләр юлбашчысы Өч-әлигъ Көнбатыш каганлык биләмәсендә бәйсезлек урнаштырган. Түргиш каганлыгы барлыкка килгән. Ә 723 елда Билгә каган һәм аның энесе Күлтәгин Төрки каганлыкны тергезгән.

Икенче Төрки каганлык таркалгач, аның урынында Уйгур каганлыгы һәм Карлук дәүләте барлыкка килгән. Карлукларның угыз ыруглары яши торган Җиде елга җирендәге сугышы VIII гасырның икенче яртысында угызларның Сырдарьяның түбәнге агымына күчеп китүләре белән тәмамланган, алар Арал алды

җирләрендә үз дәүләтләрен төзегәннәр. Бу XI — XII гасырларда бөтен Урта һәм Якын Көнчыгышны биләп торачак Сәлҗук дәүләтенең башлангычы булган.

Шул ук вакытта Ерак Көнбатышта Көнбатыш Төрки каганлык җимерекләрендә оешкан Хәзәр каганлыгы һәм Болгар дәүләте куәтләнгән. Болгарлар юлбашчысы Кубрат 610 елда Константинопольгә килгән һәм анда патрикий дәрәҗәсе алган. Төрки каганлыктагы эчке ызгыш-талаштан һәм каганлыкның үзәгеннән ерак булганлыктан файдаланып, ул мөстәкыйльлеккә ирешкән. Шулай да башкаласы Фанагориядә булган Бөек Болгар иле хәзәрләр тарафыннан җиңелгән, ә Кубрат хан уллары Дунайда һәм Идел буенда мөстәкыйль дәүләтләргә нигез салганнар.

840 елда Уйгур каганлыгы Енисей кыргызлары басымыннан җимерелгән. Карлуклар төркиләр арасында иң өстенлекле көч булып чыкканнар һәм Урта Азиядә һәм Кашгариядә Карахан дәүләте дип аталган яңа империя төзегәннәр. Төрки гадәтләр буенча аның көнчыгыш (үзәге — Кашгар һәм Баласагун) һәм көнбатыш (кече) (үзәге — Сәмәрканд) өлешләре булган.

Аннары мәйданга Кыргыз, Сир, Кумык каганлыклары килеп чыккан... XI гасырдагы фарсы авторы Гардизи фикере буенча, Иртышның үрге агымында кумыкларның кабилә берлеге оешу татар кабиләләре арасында үзара сугышка бәйле. Татар династиясенең шад дигән титулга ия кече әгъзасы уңышсызлыкка дучар булып, үз ыругдашлары төркеме белән качкан һәм Иртышның үрге агымына килеп утырган, анда кабилә берлеге оешкан, ул IX гасырда кумык дигән исем алган. Бер гасыр узгач, кумыклар дәүләте барлыкка килгән, аның башында татар династиясе утырган. Тарихи мәгълүматларга караганда, шул исемдәге татар дәүләтләре IX — XII гасырларда Ганьсу һәм Көнчыгыш Төркестан җирләрендә дә булган.

Ниһаять, X гасырда «Дәшти Кыпчак» дәүләте төзелгән. Аннары сәяси мәйданда татар-монголлар барлыкка килгән. Монголларның басып алу вакытына төркиләр дәүләт идарәсендә инде зур тәҗрибә туплаганнар. Урхун язмалары буенча «ил»нең төп максатлары куркынычсызлыкны, тәртипне һәм гаделлекне тәэмин итүдән гыйбарәт булган. Бумын дәүләтенең җимерелү сәбәбе — бәкләрнең гаделлек нигезеннән читкә тайпылулары. Ташларга шулай уелып язылган. Төрки дәүләтләрдә гаделлек идеясе иң мөһим идеяләрдән берсе булган. 1069 — 1070 елларда уйгур Йосыф Баласагунлы дәүләт белән идарә итү турында «Котадгу белек» («Бәрәкәтле белем») дигән китап язган. Мәҗбүри һәм мәҗбүри булмаган нәрсәләр арасыннан ул иң мөһиме итеп гаделлекне санаган:

> Для власти во всем справедливость — основа,
> И власть лишь во правде жива и здорова.

Хан хакимияте чиксез булмаган, хан абсолют монарх түгел. Ханнар халыкның традицияләрен, динен һәм карашларын ихтирам итәргә тиеш булганнар. Хан законнарны (тораларны) традицияләргә каршы килеп кабул итә алмаган. Хан бәйләр белән киңәшергә, моның өчен корылтайлар җыярга тиеш. Корылтайга халык та килә алган. Ханлыкка кандидатның ханнар нәселенең олы улы булуы мәҗбүри. Әгәр олы улы бар икән, сайлау процессы гап-гади хуплауга кайтып калган. Инде нәсел өзелгән очракта бәйләр арасыннан иң лаеклысын сайлап куйганнар.

551 елда Бумынны ак киезгә утыртып югары күтәргәннәр һәм Төрки Илнең беренче каганы дип игълан иткәннәр. Госман нәселенә нигез салган Госман бәйне дә хан итеп нәкъ менә шулай сайлаганнар. Риваять буенча, угызлар, барлык бәйләр һәм илнең барлык идарәчеләре җыелган. Алар Госман янына килеп киңәш тотканнар: «Без хәзер сәлҗукчеләрдән ярдәм көтә алмыйбыз. Алар үз биләмәләренең күп өлешен югалттылар, аларны татарлар җиңделәр... Син хан булырга лаек, син — бөек зат. Бу эштә бердәмлек кирәк... Без сиңа буйсынырбыз, хакимлегеңне танырбыз һәм бу җирләрдә сине яклап сугышырбыз». Госман империясе тарихы әнә шулай башланган.

Монгол империясе ханнары, Алтын Урда, Казан ханнары барысы да сайлап куелганнар. Традиция буенча, сайланган ханны алтын киезгә утыртканнар, киезнең дүрт почмагыннан дүрт кеше тотып, шушы йолага катнашучыларның шат авазлары астында югары күтәргәннәр һәм әйткәннәр: «Югарыга кара һәм Ходайны танып бел, түбәнгә кара һәм үзең утырган киезне күр. Әгәр патшалыгың белән яхшы идарә итсәң, юмарт һәм гадел булсаң, кенәзләрнең һәммәсен дәрәҗәсенә тиң рәвештә ихтирам итсәң, патшалык итүең данлы булыр, синең идарәң каршында бөтен дөнья баш ияр һәм Ходай сиңа җаның теләгән бар нәрсәне җибәрер. Әмма син моның киресен кылсаң, бәхетсез булырсың, читкә кагылырсың, шул дәрәҗәдә фәкыйрь булырсың ки: үзең утырган шушы киезне дә үзеңә калдырмаслар». Шушы сүзләрне әйткәч, киезгә сайланган ханның хатынын утыртканнар да икесен бергә киез белән берничә кат югары күтәргәннәр һәм бөтен кеше ишетерлек калын тавыш белән: «Барлык татарларның ханы һәм ханбикәсе»,— дип игълан иткәннәр. 1246 елда Гуйукны сайлаганны күргән Плано Карпини язуынча, бөек ханны тәхеткә утырту тантанасы әлеге вакыйга өчен махсус корылып, «Алтын Урда» дип аталган чатырда үткәрелгән.

Корылтай ханны сайлау гына түгел, алып ташлый да алган. Хан кабул итәргә теләгән законнар корылтай белән килешенергә тиеш булган. Сайлауга хатын-кызлар да актив катнашкан. Үгәдәй вафат булганнан соң, ханбикә Түргәнә корылтай җыйган һәм тәхеткә олы улы Гуйукны утырткан. 1251 елда хан итеп Мәнгү сайланган. Гуйукның тол хатыны Огул-Гамиш белән Чыгытай улы Бори Мәнгүне бәреп төшерү максаты белән яшерен килешү төзегәннәр. Бу килешү фаш ителгән . Әл-Гомәри хатын-кызларның Алтын Урда белән идарә итүгә катнашуы турында язган: «Мин бу илләрнең Бәркә заманнарында язылган, аннан соңгы патшалары язган күп грамоталарын күрдем. Аларда «Хатыннарның һәм әмирләрнең фикере туры килде» кебек җөмләләр бар иде». Үзбәк ханның олы хатыны, атаклы Тайдулланың йогынтысы гаять көчле булган. Аннан соң да хатын-кызлар ханбикә Сөембикәгәчә зур сәясәткә актив катнашалар. Сөембикә исә әлеге озын исемлекне төгәлли.

Төрки илнең катлаулы төзелмәсе җентекләп эшләнгән. Бәкләр (бәйләр) титулыннан һәм башка югары вазифалардан тыш түрәләрнең (чиновникларның) егерме сигез төркеме булган. Төркиләр борын заманнардан ук билгеләнгән законнар һәм кагыйдәләр буенча яшәргә омтылганнар. Кабер ташъязмаларының берсендә болай дип язылган: «Гади халык, тырыш бул! Илнең билгеләнмәләрен онытма!»

> *«Куй елының өченче аенда, егерме икенче көнендә.*
>
> *Миңа, Мәнгү Тимергә бор (шәраб) кирәк булу сәбәпле, мин Туры Баштан чын бәясеннән күбрәк итеп түләү шарты белән ярты кап шәраб алдым.*
>
> *Көз башында мин бу шәраб урынына ярты кап татлы шәраб кайтарачакмын. Әгәр дә шәрабны кайтару вакыты шушы вакыттан кичегә икән, мин шәрабны халык үлчәме буенча арттырып кайтарачакмын. Мин вафат булган очракта минем бурычны Ном Коли һәм аның нәселе түләргә тиеш.*
>
> *Шаһит: Тесәк Турмыш, шаһит: Болтаз.*
> *Бу мөһер минеке, Мәнгү Тимернеке.*
> *Минем, ягъни Турмышның язмасы Мәнгү Тимер*
> *язмасыннан соң куелган».*

Әҗәткә шәраб алып тору турында уйгур документы

Монголлар явы алдыннан төрки җәмгыятьнең нидән гыйбарәт булуын илчеләрнең шәһадәтнамәләре күрсәтеп тора. X гасырда, төгәлрәге 981 елда, Кытай императоры көньяк уйгурлар хакиме — Арслан ханга илчелек җибәрә. Илче болай язып калдырган: «Ханның төньяк Тянь-Шаньда сарае бар. Турфан тирәсендәге кырлар һәм бакчалар Кинлинг үзәненнән үткәрелгән су белән сугарыла. Бу илдә арпадан башка төрле бөртекле игеннәр үстерәләр. Бу илнең затлы кешеләре ат ите ашыйлар. Гади халык каз һәм үрдәк ите ашый. Бу илдә фәкыйрьләр юк. Әгәр дә берәрсе матди кыенлыкларга очраса, аңа бөтен җәмгыять ярдәмгә килә. Шул сәбәпле бу халыкта берәү дә вакытыннан алда үлми. Кешеләр озак яши. Халык күтәренке күңелле. Кешеләр тормышны яраталар, аеруча атка атланып йөрүгә мөкиббән. Аларның тынлы һәм кыллы музыка кораллары бар. Биредә яшәүче халык чит җир кешеләренә кеш тиресе, чәчәк рәвешендәге бизәкле ак тукымалар сата. Бу илнең кешеләре ерак сәяхәткә чыкканда үзләре белән берәр нинди музыка коралы алалар. Илдә Будда храмнары биш йөзгә якын. Моннан тыш христиан чиркәүләре һәм утка табынучыларның храмнары бар.

Будда храмнарының берсе янында китапханә урнашкан. Анда Будда дине китаплары һәм ханнарның Кытай императоры белән язышкан хатлары саклана. Бу ил кешеләре акыллы, үткен, алар намуслы һәм һөнәри сәләтләргә ия.

Илдә кыйммәтле ташларны эшкәртү эше чиктән тыш үсешкә ирешкән. Кешеләр көмештән, тимердән, алтыннан һәм яшмадан эшләнмәләр ясый беләләр. Анда берничә катлы йортлар күп. Яхшы ат бәясе — бер төргәк ефәк тукыма. Эшче атларның бәясе исә — өч аршын ефәк тукыма. Биредә хәтта ярлылар да ит ашый».

Чәчәк атучы дәүләт турындагы шушы тасвирлама үз эченә күп гасырлар буена төрки акыл тудырган иң яхшы нәрсәләрне алган. Биредә аларның үз тәҗрибәләре генә түгел, башка илләр культурасыннан алган нәрсәләр дә чагылган. Төркестанның бик белемле хакиме Цокиа 520 — 524 елларда Кытайга илчелек җибәргән, илчелек императорга дини һәм тарихи әдәбият җибәрү һәм галимнәрнең берәрсен үзенең мәгариф министры итеп билгеләү турында үтенечен тапшырган. Цокиа үзе Конфуцийны ихтирам иткән, сараена аның рәсемен элгән.

Йосыф Хас-Хаҗиб Баласагунлының «Котадгу белек» поэмасы дәүләт белән идарә итүдә тупланган тәҗрибәнең үзенчәлекле чагылышы булып тора. Идарә итүче хаким гадел генә түгел, акыллы да булырга тиеш. Көч һәм хакимият белемнән башка куркыныч.

Поистине мудр рассудительный муж,
Лишь умный — могучий, властительный муж.

Ученым дано благородными слыть,
Лишь знающий может правителем быть.

Кто мудр и учен — благородством велик,
А знаньем вершится господство владык.

И к тысячам тысяч свершений вела
Премудрость ученья — за то ей хвала!

Баласагунлы гади һәм затлы кешеләр, галимнәр, табиблар, төш юраучылар, астрологлар, җир игүчеләр, сәүдәгәрләр, терлекчеләр, һөнәрчеләр, фәкыйрьләр белән мөгамәлә итү буенча төгәл күрсәтмәләр бирә, ул этикет, әхлак һәм башкалар турында сөйли. Бу әсәр төркиләрнең сәяси аңына зур йогынты ясаган, ихтимал, моның йогынтысы ислам традицияләре тәэсиреннән ким булмагандыр.

Төркиләр X гасырда дәүләт идарәсендә Көнчыгышта да — «Дәшти Татар» да, Көнбатышта да — Хәзәр илендә һәм Болгарстанда биеклеккә ирешкәннәр.

*«Хитай, Һинда һәм Синда өлкәләрендә, Чинда һәм Мачинда, кыргызлар, келарлар һәм башкортлар илендә, Дәшти Кыпчакта, аннан төньяктагы җирләрдә, гарәп ыруларында, Сириядә, Мисырда һәм Мароккода бөтен төрки ыруларны хәзергәчә татарлар дип атыйлар. Мәгълүм һәм данлы, һәрберсенең үз гаскәре һәм үз хакиме булган татар ырулары — алтау».*

*Рәшидетдин*
*«Җамигъ-әт-тәварих». 1300 —1311*

XII гасырга татарлар шулкадәр көчәйгәннәр ки, татар кенәзләренең берсе — Кытай императорының вассалы «аңа буйсыну күрсәтми башлаган». Аңа каршы җәза отряды җибәрелгән. Моны белеп, монголлар бу уңайлы очрактан файдаланып калырга уйлаганнар. Элек-электән үк татарларга «атасы каны һәм үче» булган Тимучин кераитлар ыруы башлыгы Туграил белән алдан ук хәрби берлек төзегән. Кытайлар белән берләшеп, алар татар гаскәрен тар-мар иткәннәр, «аларның барлык ат һәм терлек көтүләрен, мөлкәтләрен тартып алганнар». Татар кешеләрен Тимучин белән Туграил үзара бүлешкәннәр. Моның өчен Алтын хан Туграилгә «Ван хан» — кераитлар ханы титулы, ә Тимучинга «Җәүт Кури» — бөек әмир титулы биргән.

Легендалар татар ыруларының монголлар тарафыннан тулысынча юк итүләре турында сөйли. «Чыңгыз хан турында Ихлас Кыйсса»да Чыңгыз хан авызыннан болай дип әйтелә: «Без нәфрәт тудырган дошманнарыбызны — татарларны, безнең ата-бабаларыбызны үтерүчеләрне җимердек, явызлыклары өчен гадел җәза бирдек, татар халкын берәмләп юк иттек, балаларын арба тәгәрмәче күчәренә куеп үлчәдек. Чынлыкта исә алар татарларның физик яктан түгел, ә сәяси өстенлеген юкка чыгарганнар, ахыр чиктә буирнур татарларын гына бетерә алганнар. Чыңгыз ханның ике хатыны: Есулун һәм Есукат татар нәселеннән булган. Рәшидетдин болай дип язып калдырган: «Хулагу ханның ат карауччысы исә Абага хан заманында хөрмәтле һәм бөек әмир булуга ирешкән Самкар нойон; Туган, Мулай һәм Кутай, Бука-Корчиның атасы Хойин татарлары ыруыннан чыккан. Җүчи хан олысында Җүчи хан улы Батыйның Буракчин атлы өлкән хатыны алчи татар ыруыннан булган, шушы ук олыс хакиме Тудай — Менгүнең хатыны Түрәкотлуг та шул ук ырудан булган, Батый әмирләре арасыннан Ит-Кара исемле өлкән әмир дә, Менгү-Тимер әмирләреннән һәм шул олыс хакиме әмирләреннән Бәк-Тимер исемле өлкән әмир дә шул ук нәселдән чыккан». Буйсындыру юкка чыгару түгел. Чынлыкта исә җиңелгәннәрне «коллар» сыйфатында төрле нәселләргә таратканнар, шул рәвешле ыру елъязмалардан югалган, әмма кешеләр үзләре яшәгәннәр, тик исемнәре генә башка булган. Әмма татарларга бу да кагылмаган. Бөтен тарихи чыганакларга даими рәвештә «татарлар»ны искә алу хас. Тарихи елъязмаларда «татар-монголлар» төшенчәсе файдаланылу татарларның исән калуын гына түгел, сәяси йогынтыларын да саклап калуларын дәлилли. Монголиядә 1246 елда булган Плано Карпини үз сәяхәте турында хикәясен болай дип башлаган: «Без — Татарлар дип атый торган Монгаллар тарихы башлана».

Чыңгыз хан дәүләт төзелешенең нәкъ менә төрки традицияләренә таянган. Мондый тәҗрибәдән башка империя төзү мөмкин булмас иде, чөнки яулап алу — бер хәл, ә дәүләткә идарә итү — бөтенләй башка эш.

Элюй Чуцайныкы дип күрсәтелә торган әлеге гыйбарә Чыңгыз ханга әйтелгән: «Ат өстендә дөньяны яулап алып була, ләкин ат өстеннән дөньяга идарә итеп булмый». Бөек илбасар моны яхшы аңлаган. Ул найман дәүләтенең мөһерен саклаучы һәм кытай киңәшчесе уйгур Тотатунгтан дәүләткә идарә итәргә өйрәнгән, законнар язар өчен кытайларны чакырган, аларның законнары нык һәм тотрыклы дип уйлаган.

Мин — кодрәтле хаким!
Иртән һәм кичен
алтын тәхеттә утырып шатланам!

*«Фал китабы». X гасыр*

Хакимиятенең чиксезлегенә карамастан, Чыңгыз ханга башбаштаклык һәм көйсезлек хас булмаган. Киресенчә, ул кабул ителгән законнарның үтәлүен таләп иткән. «Чыңгыз хан турында Ихлас Кыйсса»да аның шундый гыйбарәсе китерелә: «Моннан соң (ягъни Чыңгыз ханнан соң) килгән хакимнәр, вельможалар, баһатурлар һәм нойоннар ...Ясакны төгәл үтәмәсәләр, дәүләт эше какшар һәм өзелеп калыр. Бик тырышып тагын Чыңгыз ханны эзләрләр, тик тапмаслар... Моннан соң, биш йөз, мең, ун мең елларга кадәр, туып минем урынны алган киләчәк буыннар бу законны сакласалар һәм үзгәртмәсәләр... аларга Күктән ярдәм килер». Чыңгыз хан баш хөкемдар итеп үзенең тәрбиягә алган улы — татар Шиги Кутлугны куйган, ул уйгур язуына һәм гыйлемгә тиз төшенгән. Ул аңа мондый күрсәтмә биргән: «Хәзер, мин үземә бөтен халыкларны беркеткән вакытта, син минем колакларым һәм күзләрем булырсың. Сиңа караклыкны һәм ялганчылыкны хөкем итәргә һәм җәза бирергә кушам: кем үлемгә лаек — аңа үлем җәзасы бир; кем җәзага лаек — җәзасын алсын; милек бүлү эшләрен халык белән хәл ит. Хәл иткән эшләреңне, соңыннан башкалар үзгәртмәсен өчен, кара такталарга яз». Рәшидетдин тасвирлавы буенча, Кутугу нойон «дәгъваларны гадел хәл иткән... Ул гел: «Үз гаебеңне куркудан гына тану кирәкми»,— дип кабатлаган. Ул гаепле кешегә: «Курыкма һәм дөресен сөйлә!» — дип әйтә торган булган». Хөкем уздырмыйча беркемгә дә җәза бирелергә тиеш булмаган. Әлбәттә, чынбарлык һәрвакытта да принципларга туры килмәгән, әмма урта гасырларда ул кайсы илдә генә туры килде микән? Хәтта бүген Русиядә дә бу максатка ирешү кыен.

Әлбәттә, «Яса» күчмә культура гореф-гадәтләреннән чыгып төзелгән, ул Рим хокукы кебек нык эшләнгән система булмаган, шуңа күрә күп илләрдә җирле законнар белән алмаштырылган яки аларга яраклаштырылган. Ә инде ислам киң таралгач, үз урынын шәригатькә биргән, әмма күп кенә кагыйдәләр төгәл үтәлгәннәр. Алтын Урдада һәм төрки-татар ханлыкларында Чыңгыз хан кагыйдәләрен үтәп килгәннәр: «Кем дә кем, тәкәбберләнеп, кенәзләр сайлап куюыннан башка гына үз хакимиятен урнаштырырга теләсә, аны һич үкенмичә үтерергә кирәк». Дәүләткә идарә итү өчен «Яса»дан башка, Чыңгыз ханның гыйбарәләрен — белекләрен, башкача әйткәндә, буыннар тәҗрибәсен белү әһәмиятле булган. Кытайда 1294 елда, Хубилай хан вафатыннан соң, аның урынына хан сайлаганда өстенлек шул белекләрне яхшырак белгән кешегә бирелгән.

Татар-монголлар хан ихтыярын түгел, ә законнарны үтәүне таләп иткәннәр. Урта гасырлар гореф-гадәтләреннән чыгып караганда, күп кенә законнар һәм әхлакый нормалар кырыс булган. Кеше үтерү, ир-ат азгынлыгы, хатыннар хыянәте, караклык, талау, урланганны сатып алу, качкан колны яшерү, бурычны өч тапкыр кайтармау һәм башкалар өчен «Яса» буенча үлем җәзасы бирелгән. Хакимият вәкилләренә заложниклар алу, җинаятьче өчен аның туганнарын яки ырудашларын кулга алу тыелган. Азовтагы Венеция сәүдәгәрләренә бирелгән Бәрдебәк ярлыгында болай дип язылган: «... Ата — улы өчен, улы — атасы өчен, абыйсы — энесе өчен, энесе абыйсы өчен җәза алырга тиеш түгел». Монгол империясендә башбаштаклык принцибы булмаган.

Егерме ел өзлексез сугыштан соң Чыңгыз хан берничә гасырга тынычлык урнаштырган, бу чорда Көнчыгыш һәм Көнбатыш һич куркусыз сәүдә итү һәм аралашу мөмкинлеге алган. Ни дини, ни матди сәбәпләр буенча беркем дә эзәрлекләнмәгән. Чыңгыз хан: «Көнкүреш тормышта үзегезне — бозаулар кебек, ә мәҗлесләр һәм тамашалар вакытында тайлар кебек тотыгыз, ә дошманнар белән сугышта һөҗүм итегез, лачын кебек һөҗүм итегез; ... аяз көндә карт бүре кебек уяу; кара төндә кара козгын шикелле сак булыгыз»,— дип өйрәткән. Чыңгыз ханның холкы гади булмаган, әлбәттә. Бервакыт ул үзенең дусты Богурчы нойоннан, кеше өчен иң зур ләззәт нәрсәдә, дип сораган. Богурчи: «Кулында лачын тотып ат өстендә ауга чыгу» дип җавап биргән. Башка көрәштәшләре дә якынча шулай дигәннәр. «Юк,— дигән шунда Чыңгыз хан,— кеше өчен иң зур куаныч — үз дошманнарын җиңү, аларны куып бару, аларның мөлкәтен тартып алу, аларга газиз кешеләрнең йөзләрендә күз яшьләре күрү, аларның атларына атланып чабу, аларның хатыннарын һәм кызларын кочу». Анда ерткыч инстинктлар уйнаган, әмма ул искиткеч ихтыяр көче белән аларны тыеп торган, бөек максатларына ирешү мөмкинлеге булсын өчен аларга идарә иткән. Ул үзенең гаскәр башлыкларын да шуңа өйрәткән. Шиги Кутуку Первонада Хәрәземшаһка каршы кампаниядә Җәләлетдиннән җиңелә. Бу Чыңгыз хан исән чакта бердәнбер диярлек җиңелү була, әмма ул Чыңгыз ханны кау-

шатмый, ул: «Шиги Кутуку һәрвакыт җиңүче булырга гадәтләнгән, ул әле бервакытта да язмыш рәхимсезлеген тоймаган; менә хәзер, бу рәхимсезлекне тойгач, ул саграк булачак»,— дигән. Чыңгыз хан үзенең гаскәр башлыкларына саграк булырга кирәклеген армый-талмый кабатлап торган. Кешеләрдә бу сыйфатны ул аеруча югары бәяләгән, чөнки үзе әлеге сыйфатка тулысынча ия булган. Җәбенең Кочлукка каршы сугышта уңышка ирешүен ишеткәч, ул, атчабар җибәреп, аңа җиңүе белән артык мактанмаска кушкан, чөнки мактану кераитларның Ван ханын һәм найманнарның Таян ханын юкка чыгарды, дигән.

Чыңгыз хан — үз заманы кешесе һәм аның үз-үзен тотышы урта гасырлар гадәтләре кысасыннан чыкмаган. Танылган монголовед Б.Я.Владимирцев болай дип язган: «Чыңгыз ханга еш кына Кытайга поход вакытында искиткеч кансызлыкны, меңләгән әсирләрне кыйнауны, бөтен бер шәһәрләрнең, хәтта провинцияләрнең халыкларын суеп чыгуны сылтыйлар. Әммә игътибарлырак һәм саграк тикшеренүчеләр Чыңгыз һәм аның монголлары рәхимсезлегенең тарихи чынбарлыкка бөтенләй туры килмәвенә ышандылар. Чыңгызның кансызлыгы турында күзаллауларны, бүтән мәгълүматлардан башка да, киданнарның, кытайларның, гади сугышчыларның, генералларның, вельможаларның күпләп-күпләп монгол илбасары ягына чыгулары һәм, анда сыену урыны табып, аңа хезмәт итү мөмкинлеге алулары гына да кире кага». Ул нигездә җимерүче була алмаган, чөнки аның бөек максаты — бөтен дөньяны үз эченә алган дәүләт төзү.

Төрле-төрле шаһитлар Монгол империясендәге тынычлык һәм иминлек турында сөйлиләр, чөнки чыңгызчылар нәкъ менә шушы максатка омтылганнар. Монголлар арасында озак яшәгән Марко Поло Чыңгыз ханны болай тасвирлый: «Берәр нинди өлкәне яулап алгач, ул аның халкын кыерсытмый, аның милек хокукларын бозмый, алар арасында берничә үз кешесен калдырып, башкалары белән алга, башка җирләр яуларга китә. Буйсындырылган илнең кешеләре Чыңгыз ханның үзләрен барлык күршеләрдән яклавына, монголлар хакимияте булган җирдә бернинди дә явызлыкка юл куелмавына ышангач, шулай ук Чыңгыз ханның хаким буларак намуслылыгын күргәч, аңа җаннары-тәннәре белән тугры булалар, элеккеге дошманнардан тугры хезмәтчеләргә әйләнәләр». Ихтимал, Марко Поло монгол дәүләтен бераз идеальләштергәндер, әмма ул төп юнәлешләрне дөрес тотып алган. Аның күзәтүләрен башка елъязмачылар да раслый. Фарсы тарихчысы Мирхонд язуынча, Чыңгыз хан заманында «шәһәрләр һәм зур юллар теләсә нинди сәүдәгәрләр өчен ачык булган. Ул аларга аның биләмәләрендә һәркем (талаудан) курыкмыйча, үз башына, гади чүлмәк йөрткән кебек, үз алтынын куеп йөртерлек дәрәҗәдә куркынычсызлык тәэмин итәргә теләгән».

Кил и сакый, китергел бәдәи наб,
Көлә, уйнаю эчсеннәр бу әсхаб,
Кем уш йил тик кәчәр әйяме фани,
Әҗәлдин һич кешенең юк әмани.
Сабурдин яхшы юктыр, пишә кылсам,
Бу юлда сабыр юктыр, әндишә кылсам.

* * *

Сәламем гөлгә илт, и таң нәсиме,
Кем ирер ай колы, әхтәр нәдиме...
Сәламемне тикер ул дилстанга,
Рәхимсез бивафа җан вә җиһанга.
Сәламемне тикер ул күрке байга,
Кем орыр чәһрәсе мең тагнә айга.
Сәламемне тикер ул хуш ликага,
Камук башдин аяк абе бәкага...
Качан кылгай күземне якты ул ай,
Ирер йөзе кояш тик галәм арай.
Качан ләгълең кадәхләр нүш кылгай,
Гирешмәң бәндәне мәдһуш кылгай...
Җиһан тотты җәмалең, дад кылгыл,
Бу мискинне берәр һәм яд кылгыл...
Мәңа синсез үлемдер бу хәятым.
Сәнең миһрең белән югърылды затым...
Ирермен васлыңа даим таләпкяр,
Ничә кем төн озын булса, таңы бар...

*Харәзми*
*«Мәхәббәтнамә». 1354*

Монгол империясендә нәтиҗәле идарә өчен почта станцияләре (ям) челтәре булдырылган, алар хәбәрләр һәм әмерләр җиткергәннәр, илчеләргә, сәүдәгәрләргә һәм гади сәяхәтчеләргә хезмәт күрсәткәннәр. Үз сәяхәте вакытында почта хезмәтеннән файдаланган Марко Поло болай дәлилләгән: «Һәр 25 миль саен бөек ханның илчеләре станциягә тап булалар, монгол телендә ул «ям» дип атала, ягъни «почта атлары булган

станция». Кайбер ямнарда 400 ләп ат булган. Бөек хан җәмгысы 400 000 ләп ат тоткан. Ям шулай ук фураж, азык, сәфәр кылучылар өчен ашау-эчү белән тәэмин ителгән. Ибне Гарәбшаһ болай дип искә ала: «Гадәттә, кәрваннар Хәрәземнән чыгалар да, үз арбаларында, курыкмыйча-хафаланмыйча, Кырымга кадәр тыныч кына баралар, ә бу юл өч айга якын сузыла... Кәрваннар үзләре белән азык-төлек тә, атлар өчен азык та, озатып баручы да алмыйлар, чөнки андагы халыклар бик күп, куркыныч түгел һәм анда яшәүче кешеләрнең ризык һәм эчемлекләре дә бик күп...». Юлның һәр өлеше махсус «юл губернаторы» тарафыннан идарә ителгән, ул үз өлешендә тәртип һәм куркынычсызлык өчен тулысынча җавап биргән. Юлларны саклау өчен махсус йөкләмә кертелгән, ул «караул» дип аталган. Килүче барлык кешеләр, керүче барлык тауарлар теркәлеп барганнар, һәм махсус юл пошлинасы җыелган.

Аерым очракларда, кайбер хәбәр яки кайбер кеше бик тиз китереп җиткерелергә тиеш булганда, юлчыга лачын сурәте ясалган тактачык бирелгән; һәрбер станция, якынлашучы атларның кыңгырау тавышын ишеткәч үк, бик тиз җигеп куяр өчен алмаш атлар әзерләп куярга тиеш булган. Әлеге тактачыгы булган кеше, юлда аты егылса, каршысына очраган теләсә кемнең атын тартып ала алган. Мондый ысул белән хәрәкәт иткән очракта көнгә 250 миль үтәргә мөмкин булган. Бөек хан бу юлларның як-ягына зур агачлар утыртырга кушкан; буш җирләрдә юл баганалар, ташлар һ.б.лар белән билгеләнгән. Юлчылар елгаларны кичә алсын өчен тирә-як авылларда яшәүчеләр паром тотарга тиеш булганнар. XIII — XIV гасырларда урыслар Урдага гына түгел, Каракорымга да һич каршылыксыз йөри алганнар, ә Европа сәүдәгәрләре Кытайга да узып киткәннәр.

Әлеге системаның тарихи әһәмиятен аңлау өчен ул замандагы Европаны күз алдына китерү зарур. Жак Ле Гофф болай яза: «Урта гасыр кешеләре сукмаклардан, буталчык юллардан йөргәннәр: бу юллар ярминкәле шәһәрләр, зиярәт кылу урыннары, күперләр, елга һәм тау кичүләре кебек билгеләп куелган берничә пункт арасында салынганнар. Юлда күпме каршылык көтеп торган: куркыныч урманнар; бандитлар — урман кырында яки кыя өстендә ышеренеп утыручы рыцарьлар, вилланнар; сәүдәгәрләрдән, ә кайчак гади сәяхәтчеләрдән күперләр, кичүләр, елгалар янында алына торган бетмәс-төкәнмәс пошлиналар; начар юллар...». Ул заманнарда Чыңгыз ханның почта хезмәте белән чагыштырырлык коммуникация системасы булмаган да әле. Хәтта Римның мәшһүр юллары да «ям»нар тәэмин иткән кадәр хезмәт күрсәтә алмаганнар, ә инде кечерәк юллар турында сөйләп торасы да юк.

XIX гасырда бу система җимерелгән һәм, мәсәлән, Пржевальскийга һәм башка сәяхәтчеләргә шушы ук юллардан йөрү инде бик кыенга туры килгән. Ул юллар турында хатирәләр бары тик халык иҗатында гына сакланган, ямщик һәм аның иң кирәкле әйбере — Валдай кыңгыравы турында җырлар гына калган.

> *«Бу өлкә бары тик Татарныкы гына, ул төрле хайваннар һәм Төрки ырулар белән тулган, бар яктан да киртә тотылган, (барлык) өлешләре дә эшкәртелгән, күләме ягыннан — киң, суы һәм һавасы чиста. Кешеләре — ирләр (тулы мәгънәсендә), сугышчылары — (искиткеч шәп) укчылар. Телләре буенча алар — иң оста телле Төркиләр, тормышта — иң гаделләр, йөзләре — иң матур, матурлык буенча — иң камилләр. Хатын-кызлары — кояш, ир-атлары — тулган ай, хакимнәре — (бөек) акыллы башлар, боярлары — (баһадир) күкрәкләр. Аларда ялган да, үз араларында хәйләкәрлек тә, наянлык та юк. Аларның гадәте — куркуны белмичә, ышанычлы төстә арбаларда йөрү».*
>
> *Ибне Гарәбшаһ. XV гасыр*

Монгол империясенең олыслары Чыңгыз ханның улларына бирелгән. «Чын тарихи китапларда язылган: Хәрәземне яулап алгач, Чыңгыз хан әмере буенча, Хәрәзем һәм Дәшти Кыпчак Каялык чикләреннән алып Саксин, Хәзәр, Болгарның, аланнарның, башкортларның, урысларның һәм чиркәсләрнең иң ерак җирләренә кадәр, татар аты тоягы баскан җирләргә кадәр Җүчи ханга бирелгән. Һәм ул бу илләрдә хан тәхетенә, идарә тәхетенә урнашкан». Әмма Җүчи иртә вафат булган, ул үз олысы белән чынлап идарә итә башларга да өлгерми калган.

Җүчиның тормышы гаять фаҗигале булган. Бервакыт Чыңгыз хан юк чакта аның урдасына мәркитләр ыруы һөҗүм иткән, үзләре белән аның хатыны Буртефуҗинны алып киткәннәр. Кераитларның монголлар белән дус булган башлыгы, бу турыда ишетеп, мәркитләр юлына каршы төшкән һәм Буртефуҗинны йолып калган. Әмма мөнәсәбәтләрне ачыклау озакка сузылган һәм кире кайтканда Чыңгызның хатыны юлда малай тудырган. Бу хәл Чыңгыз ханның кече уллары Чыгытайга һәм Үгәдәйгә үз абыйлары Җүчины «законсыз туган» дип санарга сәбәп булган. Әмма бөек хан үзе Җүчины барлык балаларыннан да ныграк яраткан, шул дәрәҗәдә яраткан ки, аңа Җүчиның үлеме турында әйтергә озак җөрьәт итмәгәннәр. Фарсы чыганак-

лары хәбәр итүенчә, моны Чыңгыз ханга якын кеше — Олуг Җырчыга йөкләгәннәр. Олуг Җырчы, җаен туры китереп, төрки җыр әйткән:

> Тенгиз баштын булганды ким тондурур, а, ханым?
> Терек тубтын джыгалды ким тургузур, а, ханым?

Чыңгыз хан җавап биргән:

> Тенгиз баштын булганса тондурур олум Джучи дур,
> Терек тубтын джыгылса тургузур олум Джучи дур.

Шулчак Җырчының күзләреннән яшь агып төшкән, моны күреп Чыңгыз хан әйткән:

> Козунг йашын чокуртур конглунг голды балгаймы?
> Джиринг конгуль бкуртур Джучи ольди болгаймы?

Хан барысын да үзе аңлап алган да елап җибәргән, ә алты айдан соң үзе дә вафат булган.

Җүчи Олысына (Алтын Урдага) чынлыкта нигез салучы Батый хан булган. Лев Гумилев фикеренчә, «Батый хан — киң колачлы, эшлекле, Көнбатыш Европадагы франклар короле, император Бөек Карлдан һич тә ким түгел. Тик Карлның империясе тизрәк таркалган, ә Урда ике гасыр ярым яшәгән, аннан соң үзенең варисы итеп Мәскәү дәүләтен калдырган. Батыйның исеме үзе исән вакытта ук легендаларга чорналган. Бу хакимнең Саин, ягъни гадел, игелекле дигән ихтирамлы исем алуы да очраклы булмаган, күрәсең».

Алтын Урда баштан ук төрки-татар дәүләте буларак формалашкан, анда монгол культурасына идарәче тар даирә генә ия булган. XIII гасырда эш йөртүдә рәсми тел монгол теле булган, ә XIV гасырда инде Алтын Урда грамоталарының төп нөсхәләре төрки-татар телендә языла башлаган.

Татар-монголлар сәүдәне һәм үзләре яулап алган илләрдәге икътисадны юкка чыгарганнар дип раслыйлар, ләкин бу иң башлангыч чорга гына хас нәрсә. Сәүдә системасын вакытлыча җимерү җирле сәяси лидерларның хакимиятен какшату стратегиясе булган. Соңыннан элеккеге элемтәләр яңартылган һәм җайга салынган.

Монголларга кадәрге чорда ике транспорт юлы булган — «Бөек ефәк юлы» һәм елга буйлап — «Бөек Идел юлы». Алтын Урдадагы салым системасы һәм шәһәрләр төзелеше халыкара сәүдәне югарырак дәрәҗәгә күтәргән, шуның белән беррәттән икътисади күтәрелешкә китергән.

Салымнар утрак халыкның җан башыннан алына торган ясактан һәм күчмәләрнең мөгезле терлегенә салынган салымнан торган. Ясак җыю өчен халык исәбе алынган. Русь территориясендә беренче ике тапкыр өлешчә исәпкә алу 1245 һәм 1247 елларда үткәрелгән. Тоташ исәпкә алу 1257 елдан гына башланган, ә Новгородта 1259 елда гына уздырылган. «Суздаль, Рязань, Муром җирләренең барысын да исәпкә алдылар, игуменнарны, чернецларны, попларны, крилошаннарны, изге анага һәм владыкага табынганнарны гына санамадылар». Боларны ясактан азат иткәннәр, шуңа күрә аларны «хисапчылар» язып алмаган. Якынча шушы елларда Иранда, Әрмәнстанда, Кырымда, Дәшти Кыпчакта һәм Идел буенда да халык исәбен алганнар. Исәпкә алу кышын, ягъни авыл хуҗалыгы эшләре туктаган һәм халык биналарда яшәгән вакытта уздырылган. Халык исәбен алу салым салудан тыш ресурсларга һәм илнең экспорт мөмкинлегенә бәя бирү максатыннан да үткәрелгән.

> *«Кырым хакиме Котлык Тимер сүзе. Венеция сәүдәгәрләре Джованни Квирини әфәндегә һәм Франческа Бон әфәндегә, ханга илче итеп җибәрелгән венециялеләргә.*
>
> *Әгәр дә сезнең корабларыгыз Проватога, Калитрага яки Солдайяга килсәләр, бу өч шәһәр һәм портта, кайсысына керсәләр дә — кирәкле тауарлар алганда Рамаданга түләгән чаклы миңа түләргә тиешсез. Әгәр сәүдәгәрләрегез сәүдә итсәләр, өч процент түләргә тиешләр, сәүдә итмәсәләр, берни дә түләргә тиеш түгелләр, алардан бернәрсә дә алынмасын. Беркем дә аларга гаделсез төстә зыян китерергә яки аларны кысрыкларга тиеш түгел, әгәр кем дә булса зыян китерергә тели икән, без моңа юл куймаячакбыз. Үзләрен ышанычлы хис итеп сәүдә белән шөгыльләнсеннәр өчен без чит ил кешеләрен сакларга һәм якларга тиешбез.*
>
> *Шулай итеп, моңа (документка) ия булган кешегә моны без бирдек. Дата: (эт елында), (759 нчы) хиҗрә көнне сарайда, шәүвәл аенда, 15 нче көндә язылды».*
>
> *Котлык Тимернең Венеция сәүдәгәрләренә белдерү кәгазе*
> *1358, 20 сентябрь. Актүбә*

Чит ил кешеләре белән сәүдә оештыру өчен махсус хезмәткәрләр — «коммеркий җыючылар» тотылган, «коммеркий»га илгә тауар кертү пошлинасы, әйләнеш салымы һәм тауарны үлчәгән өчен түләмә кер-

гән. Тауар кертү пошлинасы тауарның бәясенә карамастан, аның һәрбер төргәгеннән төгәл билгеләнгән суммада алынган. Сәүдә килешүе чит ил кешеләре һәм урда кешеләре арасында төзелсә, әйләнеш салымы тауар бәясенең 3% (ахыр чиктә — 5%)ын тәшкил иткән. Тауар дәүләт үлчәвендә үлчәнсә, үлчәгән өчен түләмә тауар бәясенең 1,5% ын тәшкил иткән. Бу түләмә контрагентка сәүдә килешүе чит ил кешеләре арасында төзелгән очракта да түләнергә тиеш булган. Әйләнеш салымы «тамга» дип аталган, аны «тамгачы», ягъни ил чиген үткән әйберләргә тамга салучы (таможенник) җыйган. Үлчәгән өчен түләмә «тартанак» дип аталган, аны «тартанакчы», ягъни үлчәүче җыйган. Биредә ике яктан да (хан тамгачысыннан һәм чит ил консулыннан) вәкилләр билгеләнгән, алар үлчәүнең төгәллегенә, сатучы һәм сатып алучының законда каралган сәүдә салымын һәм үлчәү җыемын түләүләренә күзәтчелек иткәннәр.

Кыйммәтле асылташлар, энҗе-мәрҗән, алтын-көмеш, алтын канитель сатучыларга сәүдә салымы салынмаган. Бу әлеге кыйммәтле әйберләр Урдага күбрәк кертелсен өчен эшләнгән. Кайбер тауарларга салым бик зур булган. Җанбәк ханның Азовтагы Венеция сәүдәгәрләренә бирелгән ярлыгында мондый юллар бар: «Әгәр дә Венеция сәүдәгәрләреннән берәрсе эшкәртелмәгән тире үзләштерә яки сатып ала икән, ул безгә коммеркий түләргә тиеш: иң зур коммеркий — йөз тире өчен — илле, иң кечесе — кырык, Генуя кешеләрендәге кебек». Мондый зур салым эчке җитештерүгә ярдәм йөзеннән салынган. Кырымда һәм Кара диңгез буеның төньягында үзләренә бүлеп бирелгән кварталларда таверна тотучы чит ил кешеләре «айлык» («ай саен җыелучы салым») һәм ясак («ел саен җыелучы салым») түләүдән азат ителгәннәр.

Алтын Урданың Кырым портларыннан Италия дәүләтләренә һәм Көнбатыш Европаның калган өлешенә чыгарган тауарларына анализ шуны күрсәтә: илнең икътисады өчен сәүдә итү ясак җыюдан әһәмиятлерәк булган. Экспорт тауарларының иң мөһиме — ашлык, иң беренче чиратта — бодай, чөнки ул заманда Европада ачлык гадәти күренешкә әйләнгән, шуңа күрә анда бодай аеруча кадерле булган.

XIII гасыр ахырыннан башлап Генуя кешеләре мәрсин (осетр) һәм башка балыклар сатып алганнар. Италия кешеләре белән сәүдә итүдә төп тауар — тоз. XIV гасырда Кефе шәһәре аша ефәк, күн, мех, мамык, мастика, металл һәм файдалы казылмалар сәүдәсе барган. Коллар да тиз йөрешле тауар саналган, аларга ихтыяҗ һәркайда зур булган — Якын Көнчыгышта да, Урта диңгез буенда да һәм Көнбатыш Европада да. Коллар белән сәүдә итү Алтын Урда барлыкка килгәнче үк башланган һәм Урда таркалганнан соң да дәвам иткән. Коллар арасында чиркәсләр, төрекләр, лазлар, венгрлар, урыслар, кыпчаклар, татарлар һәм башкалар очраган. Урыслар колларның биштән бер өлешен генә тәшкил иткәннәр. 1381 елда Генуя халкының 4% тан алып 10% ка кадәр өлеше башлыча Кырым базарларыннан сатып алынган коллардан торган.

Тауарларны су юлыннан йөртүгә киткән чыгым, коры җирдән йөрткәнгә караганда азрак булган, шуңа күрә сәүдә эшендә Италиянең диңгезчелек белән шөгыльләнүче дәүләтләре алга чыккан, аларның Кырымда үз шәһәрләре һәм үз колонияләре булган. Юлай Шамил оглы мәгълүматларына караганда, 1390 елда Кефе шәһәре Генуяга чыгарыла торган ашлыкның 14% ын, 1391 елда — 10% ын, 1392 елның декабреннән 1393 елның июненә кадәр 6% ын тәэмин иткән. Биредә Венеция һәм башка шәһәрләргә чыгарылган ашлык исәпкә алынмый. Алтын Урда Европаның башка дәүләтләре, шулай ук Һиндстан белән дә сәүдә иткән, Урда Һиндстанга бик күп ат саткан.

Сәүдәгә этәргеч бирү өчен акча реформалары үткәрелгән. Болгарда сугыла торган көмеш дирһәмнең авырлыгы Бәркә идарә иткән чорда 1,56 граммнан 1,365 граммга кадәр кимегән. Туктай хан 1,485 граммлы акча керткән. Үзбәк хан заманында дирһәмнең авырлыгы 1,47—1,49 грамм булган. Җанбәкнең ике башлы бөркет ясалган тәңкәләре 1,52—1,56 граммга җиткән. Алты дирһәм алтын тәңкәгә тәңгәлләштерелгән, ул алтын (яки гарәп телендә динар) дип аталган, авырлыгы 9,12 грамм булган. 120 дирһәм — сот (182,4 грамм), 300 дирһәм — кадак яки фунт (456 грамм) булган. Сарай дирһәме Алтын Урдада гына түгел, әйләнә-тирә илләрдә дә өстенлек иткән. Русия Алтын Урданың финанс һәм икътисад системасына кергән. Урыс телендә казна, казначей, деньги, алтын, таможня һ.б. кебек татар алынмалары барлыкка килү очраклы хәл түгел.

Халыкара сәүдәне җанландыруда шәһәрләр әһәмиятле роль уйнаганнар, Батый хан чорыннан башлап аларның саны бик тиз арткан. Дәүләтнең башкаласы Сарайда 75 мең кеше яшәгән, ул үз заманында Флоренция, Генуя, Милан, Париж белән чагыштырырлык дәрәҗәдә гүзәл һәм зур шәһәр булган. Шәһәрләр сәүдәгәрләрнең куркынычсызлыгын тәэмин иткәннәр, аларгакирәкле инфраструктура — базарлар, биналар, келәтләр, тамга пунктлары (таможнялар) тәкъдим иткәннәр. Моның белән алар сәүдә әйләнешен арттырганнар, димәк, салымнар да арткан. Баш шәһәр Сарай, соңыннан Яңа Сарай халыкара сәүдәнең стратегик чатларында урнашкан һәм халыкара сәүдә үзәкләре вазифаларын башкарган. Шәһәрләр, сәүдә эшчәнлеген җиңеләйтү максатында, сәүдә юнәлешләре буйлап салынганнар. Күп кенә торак урыннар елгалар киселешендә яки атлар алмаштыра торган станцияләр янында төзелгән. Күпсанлы шәһәрләр төзү үзе үк сәүдә итү нәтиҗәсендә барлыкка килгән акча чыганаклары булуны аңлата. Хакимият тырышлыгы аркасында сәүдә эше Батый хан идарә иткән чорның азагына ук кискен үсешкә ирешә.

Шәһәрләр һөнәрчелек үзәкләре дә булып торганнар. Л.Ю.Якубовский хәтта Сарай Бәркәнең «металлургия сәнәгате» турында язган, ул «шәһәрләрнең һәм шулай ук авылларның металл эшләнмәләргә: көрәккә, балтага, пычкыга, уракка, кадакка һәм күптөрле салкын коралга» ихтыяҗын канәгатьләндергән. Алтын Урда шәһәрләрендә керамика торбалардан төзелгән сууткәргеч һәм агач торбалардан ясалган канализация эшләгән, фонтаннар һәм көнчыгыш мунчалары да күп булган.

Корыб кашы йәсен кара күздәрең,
Атар керпек укын мәңа күзләрең.

...Алыр сабыр җандан, күңелдән карар,
Кемә бакса бер кат кыйа күзләрең.

Күңелләрне баглаб кара зөлфенә,
Усанмасмы, җанлар ала күзләрең.

Ни йулдан бу Сәйфе Сараиның уш,
Түкеб канын эчәр кана күзләрең.

Әгәр «Һай!» димәсәң, җәһанны хараб
Кылыр гамзә белән йәнә күзләрең.

*Сәйф Сараи. XIV гасыр*

Шәһәрләрдә фән һәм сәнгать үскән. Алтын Урда шәһәрләрендә күп еллар яшәгән, төрки телне яхшы белгән фарсы тарихчысы ибне Гарәбшаһ Сарай турында болай дип язган: «Сарай гыйлемнең бергә тупланган үзәгенә вә бәрәкәт чишмәсенә әверелде, кай арада галимнәрнең һәм мәшһүр шәхесләрнең, әдипләрнең вә маһир затларның, тагын күптөрле уңган-булганнарның каймагы шунда җыелып өлгерде; мондый алтын кулларның әле Мисырдагы халык күп яшәгән шәһәрләрдә дә, аның авылларында да җыелганы булмады». Яхшылап уйланылган сәяси система, алга киткән мәдәният һәм гомумдәүләт теле татар этносәяси җәмгыяте барлыкка килүгә нигез булган.

Сәяхәтчеләр Алтын Урда шәһәрләрен катлаулы космополитик үзәк буларак тасвирлыйлар, аларда татарлардан тыш монголлар, аланнар, кыпчаклар, чиркәсләр, урыслар, греклар яшәгән, аларның үз торак кварталлары һәм базарлары булган. Сарайда православие епархиясе 1260 елларда барлыкка килгән һәм XV гасыр ахырына кадәр эшләп килгән. XV гасырның ахырына Сарайга, Үкәккә, Болгарга, Кырымдагы һәм Иделдәге күп кенә сәүдә шәһәрләренә францисканлылар барып чыккан. Доминиканлылар Кефедә, Танада һәм башка шәһәрләрдә актив булганнар. Католик хакимият Сарай шәһәрендә күпсанлы епархияләргә һәм архиепископлыкка ия булган. Бу оешмаларның максаты миссионерлар эшчәнлеген җәелдерүдән һәм мөсафир сәүдәгәрләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән гыйбарәт булган.

Әй ханиям, ханиям!
Маңлайдан аккан ачы тир
Табанга җитсә, тоз булыр;
Колакка төшкән суык сүз
Йөрәккә җитсә, боз булыр;
Агач башын җил борыр,
Адәм башын сүз борыр.

*«Идегәй». XV гасыр*

Алтын Урда Монгол империясеннән Батый хан вакытында ук аерылып чыга башлаган. Сәбәбе — бөек Гуйук хан белән шәхси мөнәсәбәтләрнең киеренкелеге. 1238 елда Батый хан бөек хан Үгәдәйгә язган хатында аның улы Гуйуктан һәм Чыгытай улы Боридан зарланган, ул алар белән мәҗлестә ачуланышкан. Хан улларын кире Монголиягә кайтарганнар. Үгәдәй вафатыннан соң Гуйук бөек хан булган һәм Бату үзәк хөкүмәт белән гаять киеренке мөнәсәбәттә калган. Ул Гуйукны бөек хан итеп танырга теләмәгән, ә нәселдә иң олы ир-ат буларак, аны сайлауга фатиха бирергә тиеш булган, әмма ул үз фатихасын бирмәгән. Җучи олысы белән Монгол империясе арасындагы мөнәсәбәтләр шул сәбәпле бозыла башлаган. Соңыннан да империя олыслары арасындагы салкынлыкка сәбәпләр табылып торган.

1261 елда Мисыр солтаны Бибарс Бәркә ханга Иран хакиме Хулагуга каршы изге сугыш тәкъдим итеп илчелек җибәргән. Бәркә, мөселман һәм Хулагу ханның олы абыйсы буларак, аның Иранны яулап алуы турында болай дигән: «Ул мөселманнарның барлык шәһәрләрен, мөселман ханнарының барлык йортларын җимерде, дусларны дошманнардан аера алмады, туганнар белән киңәшмичә хәлифне юкка чыгарды. Әгәр Мәңгелек Тәңре ярдәм итсә, мин гаепсез коелган кан өчен аны җавапка тартачакмын». «Һәм ул үзенең гаскәр башлыгы һәм Тутар туганы булган Нокайны утыз мең җайдак белән сугышның алгы сызыгына аның

каны өчен үч алырга җибәргән», — дип язган Рәшидетдин. Бәркә ханның Мисыр мәмлүкләре һәм Чыгытай ханлыгы белән берләшүе аркасында Иран чолганышта калган. Монгол империясе таркала башлаган. Аерым олысларның мәнфәгатьләре илнең бөтенлегеннән өстенрәк була барган.

Низаг тудыручы башка бер фактор — күчмә һәм утрак культуралар арасында көрәш. Тора-бара шәһәрләшү киңрәк колач алган, ислам өстен дингә әйләнгән. Моңа бәйле рәвештә ислам дини гыйлеменең, фәннәрнең, әдәбиятның, архитектураның роле көчәйгән. «Ханнарның мөселманлыкка һәм Урта Азия-Иран тибындагы шәһәр көнкүрешенә йөз тотуы аркасында,— дип яза Г.А.Федоров-Давыдов,— көньяк урыс даласында, исламнан ерак җирдә, һич көтмәгәндә, күчмә халыкка бөтенләй ят булган урта гасыр көнчыгышының шәһәр культурасы — су сибү касәләре һәм мәчетләрдәге мозаика бизәкләре, гарәп астрологлары, фарсы шигырьләре һәм мөселман рухи галимлеге, Коръәнне шәрехләүчеләр һәм математика-алгебрачылар, нәфис орнамент һәм каллиграфия культурасы балкып чәчәк ата». Алтын Урданы исламлаштыру шәһәр культурасының өстенлеген аңлаткан, ул Чыңгыз ханның «Яса»сы ролен какшатып, чыңгызчыларның традицион күчмә цивилизациясен кысрыклаган. Бу процессны Үзбәк ханның «ислам революциясе» тизләткән, әлеге чорда Алтын Урда үз үсешенең иң югары ноктасына җиткән. Ризаэтдин Фәхретдин язганча: «Һичшиксез, Үзбәк хан — күренекле хаким, аның заманында Алтын Урда моңарчы күрелмәгән үсешкә һәм куәткә ирешкән, әмма аның бер сәяси хатасын инкарь итеп булмый: ул, Мәскәү кенәзлеген көчәйтеп, үзе дә аңламыйча, Алтын Урдага каршы яшерен генә җитди дошман әзерләгән. Үзбәк хан үзара сугышып торучы вак кенәзлекләрне гел бергә туплаган. Шуның аркасында урыслар үзләренең көчләрен тоеп алганнар». Үзбәк хан, Иван Калитаны Русьның бөек кенәзе итеп билгеләп, урыс кенәзләренең үзара сугышын туктаткан. Моны сәяси хата итеп шәрехләү кыен, бу чыңгызчыларның үз биләмәләрендә тынычлык урнаштыру принцибы булгандыр. Шундый ук тарихи миссияне Кытайда Хубилай хан үтәгән, ул хакимлек иткән чорда һәрвакыт дошманлашып яшәгән төньяк һәм көньяк татулашкан, бу исә кытайларга монголлар хакимлеген җимерү өчен алшартлар тудырган. Урыслар Алтын Урдага дошман булган дип раслау белән дә килешеп булмый, киресенчә, ул заманда урыслар Сарайга карата бик лояль булганнар, һәрхәлдә, бу империянең башка биләмәләре лояльлегеннән һич тә ким булмаган. Төп киеренкелек башка яссылыкта — күчмә цивилизация һәм шәһәр цивилизациясе арасында булган.

Алтын Урда Җаек буйлап ике канатка бүленгән. Уң (көнбатыш) канатта утрак элемент өстен булган, сул (көнчыгыш) канатта исә башлыча күчмә тормыш нормалары хакимлек иткән. XIII гасыр уртасында Алтын Урданың күпчелек халкы, шул исәптән хакимлек итүче элита да, күчмә тормыш алып барган. Идел буенда үз башкаласы Сарайга нигез салган Батый ханны чит ил сәяхәтчеләре дала лагеренда очратканнар. XIV гасырда хакимлек итүче югары катлам шәһәр үзәкләренә урнаша башлаган. Хәтта Үзбәк ханның да тормышы тулысынча утрак булмаган. Тик шулай да Бәркә хан хакимлек иткән вакытны күчмә тормыштан баш тартуның башлангычы дип билгеләргә мөмкин. Юлай Шамил углы, Марко Поло хәбәрләренә таянып, хаким катлам традицион рәвештә «күченеп» түгел, ә Сарайдан Болгарга (аны җәйге башкала итеп файдаланганнар) барып йөргән дип фараз итә. Болгар Бәркә ханны ислам үзәге буларак җәлеп иткән. Өстәвенә Туктай белән Үзбәкнең акча реформаларына кадәр дәүләтнең төп акча сарае анда урнашкан. Болгарның чәчәк ату чоры XIII — XIV гасырларга туры килүе очраклы хәл түгел.

Алтын Урдада дала олыслары, иң беренче чиратта Нугай Урдасы, күчмә үзбәкләр, аннан соң казахлар да мөһим роль уйнаганнар, ләкин күпсанлы шәһәрләрнең үсеше, елга буйлап сәүдә итү утрак тормышка өстенлек биргән. Иделнең роле Азия өлешендәге яки Кырымдагы кәрван юллары роленнән ким булмаган. Экспортта бодай һәм башка кыяклы ашлык культураларының әһәмияте арткан, шуңа күрә утрак халыкның роле көчәйгән. Шәһәрләшү җир игүчеләрнең, һөнәрчеләрнең, сәүдәгәрләрнең саны артуга китергән. Моның белән бергә яшәеш кыйммәтләре һәм тормыш рәвеше дә үзгәргән. «Бөек Яса» урынын шәригать алган, ә Чыңгыз ханның әхлакый кодексы нигездә онытыла барган. Идегәйнең атасы Балтычак бәкләрбәге булган һәм хан белән бергә 1378 елда Туктамыштан җиңелгән. Җиңүче Туктамыш Балтычакка үзенә хезмәт итәргә тәкъдим иткән, әмма Балтычак горур рәвештә баш тарткан һәм җәзалап үтерелгән. Ә Чыңгыз хан исә мондый очракларда кешене иреккә җибәрә торган булган. Баһатурларның рыцарьлык дәвере ахырына якынлашкан. Болар барысы да тирәнтен нәтиҗәләргә китергән. Цивилизацияләр арасында конфликт өлгереп җиткән.

Шул ук вакытта сәяси аренада чыңгызчылар варисы булырга хокуклы талантлы гаскәр башлыкларының һәм сәяси лидерларның мәнфәгатьләре бәрелешкән. Иң көчле шәхесләр арасында без Нугайны, Мамайны, Идегәйне күрәбез, асылда исә алар ханнарны үз белдекләре белән билгеләп куйганнар, әмма үзләренең тәхеткә утырырга хокуклары булмаган. Идегәй турында: «Аның заманында солтаннарның исеме генә бар, әһәмиятләре юк»,— дип сөйләгәннәр. Шушы бөек шәхесләрнең өчесе дә — Бөек Дала вәкилләре. Гаскәриләрнең һәм сәяси эшлеклеләрнең гайрәте нәкъ менә далада сакланган. Дәүләт системасы исә тәкәббер лидерларның югары хакимият системасына табигый кушылу механизмнарын эшләп чыгара алмаган,

шуңа күрә аны көчсез ханнарны өскә чыгаручы династия принцибы ярдәмендә чын хакимияткә ия булган әмирләр, бәкләрбәкләре, бәкләр арасында каршылыклар эчтән таркаткан. Сәяси реформалар кирәк булган. Моны сәүдә һәм финанс системасы да, алга киткән мәдәният тә таләп иткән. Алтын Урда сәяси үзгәртеп корулар чорына килеп җиткән, әмма сыйфатый әверелеш килеп чыкмаган. Юлай Шамил углы дүрт бәк системасын «парламент алды» дип атарга мөмкин дип саный. Дүрт «хаким нәселнең» лидерлары дәүләт эшләренә күмәк идарә итү системасы аша катнашканнар, шул рәвешле алар ханның хакимиятен тигезләп торганнар. Хан билгеләп куя торган диваннан аермалы буларак, дүрт бәк «җир» дип аталучы мәгълүм халыкның өстен катламы вәкилләре булганнар. Дүрт бәк-карачы «дәүләт советы»н тәшкил иткәннәр, ул идарә итүдә мөһим роль уйнаган — ханнарны тәхеттән төшерү, сайлау һәм хан вазифаларына кертү, дәүләтнең хәрби һәм чит илләр белән эшләрендә катнашу белән шөгыльләнгән. Нәкъ менә шушы дүрт карачы хан сайлаган мизгелдә күтәрү йоласын үтәгәннәр: ханны киезгә утыртып, киезнең дүрт почмагыннан тотып өч тапкыр күтәргәннәр, аннан соң ханны чатыр тирәли күтәреп йөргәннәр һәм тәхеткә утыртып кулына алтын кылыч тоттырганнар. Дүрт бәк арасыннан иң башы бәкләрбәге — «бәкләрнең бәге» («бәйләрбәе») титулын йөрткән. Ул армия эшләре өчен җавап биргән, ахыр чиктә армиянең бер өлешенә идарә иткән. Дүрт карачы хупламаса, ягъни документка хан мөһере белән рәттән үз мөһерләрен куймаса, ханның бер генә декреты да законлы булмаган. Юлай Шамил углы фикеренчә, шушы нигездә бу дүрт бәкне закон чыгаручы органга тиңләргә мөмкин.

Алтын Урдада Европадагыларга охшаш процесслар барган, әмма Европада цивилизацияләр бер-берсе белән конфликтка кермәгәннәр, алар шәһәр культурасын һәм яңа сәяси системаны үстерү юлыннан эзлекле барганнар, ә Алтын Урдада бөтен энергия эчке көрәшкә сарыф ителгән.

Алтын ияр, акбүз ат
Төшеңдә тотып син менсәң,
Ат-морадка җиткәнең!
Күккә табан син очсаң —
Йорт алдына чыкканың!
Күктә йөзгән фирештә,
Аларга барып сөйләсәң —
Ирәннәр култыклап йөргәнең!

*«Идегәй»*

Нугай исә хан тәхетенә хәйлә белән Туктайны утырткан һәм аңа үз кызын кияүгә биргән. Нугай чит илләргә кагылышлы эшләрне алып барган, Мисыр мәмлүкләре һәм Византия белән элемтәдә булган. Ул хәтта Мануэль VIII Палеологның кызына өйләнгән. Нугай кызы мөслимә булган, һәм аны ире дә, тирә-яктагылар да кысрыклаган. Нугай, нәфрәтләнеп, атчабар җибәреп хәбәр иткән: «Күпме кыенлыклар күрүем кешеләргә мәгълүм, Саин хан тәхетен хәйлә белән сиңа бушатыр өчен үзем хыянәткә һәм мәкергә катнаштым, ә хәзер ул тәхеттә карачы Салҗидай (хан хатыннарының берсенең этисе) идарә итә. Әгәр (улым) Туктайның безнең арада ата-ул мөнәсәбәтләрен ныгытасы килсә, Салҗидайны Хәрәзем янындагы йортына кайтарып җибәрсен». Туктай риза булмаган: «Ул миңа атам кебек, ул — минем остазым һәм ул — карт әмир, мин аны ничек дошман кулына бирим?» «Нугайның бик акыллы һәм сәләтле Чапай исемле хатыны Туктай янына илче булып берничә тапкыр барган. Аның өч улы булган: зурысы — Җүке, уртанчысы — Еке һәм кечесе — Тури. Алар Туктайның берничә мең кешесен, байлыкка кызыктырып, үзләренә буйсындырганнар, аларны Идел аша чыгарып, дорфа һәм золымлы кулларын Туктай биләмәләренә сузганнар һәм анда үз белдекләре белән идарә итә башлаганнар. Туктай, ачуы килеп, (ул) меңнәрне кире кайтаруны таләп иткән. Нугай шулай ук риза булмаган һәм әйткән: «Мин ул кешеләрне Туктай миңа Салҗидайны, аның улы Яйлагны һәм Тама-Туктуны җибәрсә генә кире кайтарачакмын». Шуның аркасында ике яктан да чуалыш һәм дошманлык ялкыны кабынып киткән».

Тагын да билгелерәк фигура — Мамай, аның исеме урыс елъязмаларында 1361 елда Тимер Хаҗига каршы оештырылган яшерен сөйләшүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән, гәрчә күпкә алдарак ибне Халдун аны «Бирдебәкнең өлкән әмирләреннән берсе» дип атаса да. Мамай — талантлы гаскәр башлыгы һәм тәҗрибәле сәяси интриган. Аның күтәрелеп китүенә Бирдебәк ханның кызына өйләнү ярдәм иткән, шул рәвешчә, ул хан кияве (гүргән) булып киткән һәм шуның аркасында зур хокукларга ирешкән, әмма барыбер тәхеткә утыру хокукы булмаган. Тик тәхеткә омтылышы шулкадәр көчле булган ки, ул хәтта «Мамай — гадел хөкемле хаким» дигән титул язылган акча да суктыра башлаган. Һәм ул Нугай яки Идегәй кебек тәхеткә үзе утырткан чыңгызчылар аркылы идарә иткән. Аннары Мәскәүгә яу чабып караган. Ул уңышка ирешкән очракта Алтын Урда икегә бүленгән булыр иде. Ләкин Мамайны Куликово кырында тар-мар иткәннәр, бу хәл аның эшчәнлеген юкка чыгарган һәм Туктамышның күтәрелүенә ярдәм иткән.

Тимер киемен кия иде Мамай,

Батыр булам, дия иде Мамай,
Күпме кан агызды Мамай,
Кан коярга ашкынды Мамай,
Калмыкларны кырды Мамай,
Булат кылычын кайрады Мамай,
Юргаларны иркәләде Мамай,
Мал-туарның барлык дүрт төрен
Чаган җирендә асрады Мамай,
Баганадай тузан куптарып,
Бия көтүләре сауды Мамай,
Тирә-ягында дус-ишләрең,
Иптәшләрең иде, Мамай,
Бәхетсез бер кара көндә
Синсез калдым мин, Мамай!

*«Анасы Кара-үлйәкнең*
*Мамай турында сыктавы»*

Алтын Урда таркалу сәбәпләрен төрлечә фаразлыйлар. Иң фантастик фаразлар таркалу сәбәпләрен Мамайның Куликово кырында җиңелүенә һәм 1480 елда Уграда торуына кайтарып калдыралар. Башка авторлар төп гаепне эчке низагларда һәм Аксак Тимер һөҗүмендә күрәләр, биредә, әлбәттә, дөреслек бөтенләй юк ук түгел, гәрчә каршы торырга сәләтсезлекне аңлату зарур булса да. Таркалу сәбәпләре сыйфатында «Бөек ефәк юлы»на альтернатив рәвештә Азиягә кәрван һәм су юллары барлыкка килүне дә атыйлар. «Идегәй» дастаны Алтын Урданың җимерелү сәбәбе итеп Туктамыш белән Идегәй арасындагы дошманлыкны күрсәтә.

Дәүләтнең көчсезләнүенә китергән объектив сәбәпләр дә булган, әлбәттә, югыйсә нәселләр арасындагы дошманлыкны һәм шулкадәр фаҗигале нәтиҗәләрне аңлату мөмкин түгел. Урыс елъязмалары болай дип язганнар: «Ходай кешеләргә Көнчыгыш илләре астындагы Орначь һәм Хозоторокань, һәм Сарай, һәм Бездеж шәһәрләренә, һәм алар илендәге башка шәһәрләргә чир җибәрде, ул чир Бесерменда да, Татаровода да, Орменда да, Обезда да, Жидта да, Фрязларда да, Черкасларда да һәм анда яшәүче бөтен кешеләрдә дә көчле булды, үлгәннәрне күмәргә кеше калмады». Алтын Урда чикләренә Көнбатыштан чума килеп җиткән. Европаны бу чир демография ягыннан гына түгел, икътисад һәм технология ягыннан да артка алып ташлаган. Алтын Урданы да шул ук язмыш көткән.

Юлай Шамил углы раслаганча, «Алтын Урдада 1359 елда Бирдебәк үлеменнән соң килеп чыккан «олы болгак» — 1340 елда Алтын Урда территорияләренә килеп кергән «Кара Үлем»нең турыдан-туры нәтиҗәсе». Бубонлы чуманың алга таба — 1345—1346 елларда көчәеп-көчәеп китүе төп шәһәр үзәкләренең җимерелүенә китергән, моның белән бергә сәүдә һәм барча икътисад та таркалган. Кәрван юллары да бетүгә йөз тоткан, кенәзләр бер-берсенә каршы сугышкан, ил вак-вак аерым олысларга таркала башлаган. Дүрт төп нәсел бәкләре чыңгызчыларның төрле вәкилләрен яклаган, бу исә сәяси хакимиятнең элеккеге нигезен җимергән. Алтын Урда һәлакәткә дучар ителгән.

Бирдебәк үтерелгәннән соң Туктамышның тәхеткә утыруына кадәр, ягъни бары тик 20 ел эчендә ике дистә хан алмашынган: «Бирдебәк (1357—1359), Кульпа (1359 елның җәе — көзе), Нәүрүз (1359 елның көзе — 1360 елның җәе), Хызр (1360 елның җәе — 1361 елның җәе), Хәлифә (1361 ел җәенең 2 атнасы), Урда шәех (1361 ел җәенең 1 ае), Тимер Хуҗа (1361 елның җәе — көзе), Килдебәк (үзен хан итеп игълан иткән, 1361 елның көзе — 1362 елның җәе), Габдулла (1362 елның җәе — көзе), Мөрит (1362 елның көзе — 1363 елның башы), Мир Булат (1363 елның башы — 1364 елның көзе), Газиз шәех (1364 елның көзе — 1367 елның җәе), Габдулла (икенче тапкыр, 1367 елның җәе — 1370 елның язы), Мөхәммәт Бүләк (1370 елның язы — 1374 елның көзе), Орыс (1374 елның көзе — 1375 елның көзе), Каганбәк (1375 елның көзе — 1377 елның көзе), Гарәбшаһ (1377 елның көзе — 1378 елның көзе), Туктамыш (1378 елның көзе — 1395 ел)». Нәкъ менә шушы чорда Алтын Урдада лидерлыкка омтылган күпсанлы дәгъвачылар үз акчаларын сукканнар, әлеге күренеш үзе үк дәүләтнең үзәге таркалуын күрсәтеп тора. Урыс елъязмачысы болай дип дәлилли: «Гладу же въ нихъ велику надлежащу и замятне мнозе и нестроению надълзе пребывающу и не престающе другъ на друга въстающе и крамолующе и воююще межи собою, ратящеся и убивающеся». Эчке низаглардан йончыган Алтын Урда Русия кенәзлекләренең көчәеп килүче каршылыгын тоя башлаган, Литва илнең көньягына һөҗүм башлаган, илнең көнчыгыш өлеше көнбатыш өлешенә һөҗүм иткән.

Туктамыш — чыңгызчыларның Алтын Урда таркалган чордагы иң күренекле вәкиле. Аның дошманы — күренекле гаскәр башлыгы һәм сәяси эшлекле, чыңгызчы булмаган Идегәй. Алар арасындагы көрәш — Алтын Урданың озын тарихында соңгы сәхифә. Бу көрәштә Идегәйнең тәкәбберлеге дә, дала һәм утрак цивилизацияләр арасындагы каршылыклар да, Туктамышның, Идегәйнең һәм Аксак Тимернең шәхси мөнәсәбәтләре дә чагылган.

Анда купты бер орыш —
Идегәйнең орышы,
Дөньяларда булмаган
Ир Идегәй сугышы.
Румдан купкан Искәндәр —
Ул да андый орган юк,
Дарап улы Рөстәм —
Ул да андый орган юк.
Юзекәй улы ир Чыңгыз
Бер сукканда ун суккан,
Ташка сукса, ут чыккан,
Җиргә сукса, су чыккан,
Иргә сукса, кан чыккан,
Канга сукса, җан чыккан;
Ир Идегәй органда
Аннан өстен орышы!

*«Идегәй»*

Ибне Гарәбшаһ язган: «Идику (ягъни Идегәй) үзе өчен курка башлаган, Туктамышның холкы явыз булганга, ул, кинәт бәхетсезлеккә очрамас өчен, һәрвакыт сак булган, качарга кирәклеген күрсә, һәрвакыт качарга әзер торган. Ул Туктамышны күзәтә, илтифат күрсәтә һәм ялагайлана башлаган. Ләкин бервакыт төнлә кәеф-сафа корып утырганда, касә-йолдызлар ләззәти тирәлектә бөтерелгән һәм шәраб солтаны гакылларга идарә иткән бер мәлдә; гакыл уты әле сүнгән, әле кабынган бер мәлдә, Туктамыш Идегәйгә әйткән: «(Килер) синең һәм минем өчен бер көн, (шул вакытта) бәла килеп сине фәкыйрьлеккә чыгарыр, тормышның мул сыйларыннан соң сиңа ач торырга туры килер, үлем гамәлләреннән гомер күзең төш күрер». Идегәй моны уздырып җибәрмәкче булып шаяртып әйткән: «Хакимебезнең, ханыбызның һич гаепсез колына ачуланып үзе утырткан агачны корытуын, үзе салган (бинаның) нигезен җимерүен Ходай күрсәтмәсен». Шуннан соң ул (Идегәй) йөзенә юашлык, күндәмлек, мескенлек, түбәнчелек чыгарган, ә үзе шикләнгән нәрсәләренең дөреслегенә ышанып, эчтән генә моннан исән-имин чыгып котылу турында уйлаган, моның өчен ул бөтен үткенлеген һәм зирәклеген эшкә җиккән, чөнки үз эше турында үзе кайгыртмыйча, әзрәк котәргә теләп, кичектерсә, (аның белән) солтан үзе шөгыльләнәчәген аңлаган. Ул ханның түрәләре һәм хезмәтчеләре яныннан тиз генә, сиздермичә генә, йомышын үтәргә чыккандай оялган булып узып киткән дә, бик нык дулкынланып, Туктамышның ат абзарына юнәлгән һәм кирәк була калса дип әзерләнгән, иярләнгән яхшы токымлы, җитез атка атланган, үзенә тугры бер хезмәтчегә әйткән: «Мине күрәсе килгән кеше мине Тимер яныннан табар; бу серне минем чүлне кичкәнлегемә ышанганчы беркемгә дә чишмә». Идегәй Тимер янына килгән дә әйткән: «Син ерак илләргә, кыргый һәм ташланган җирләргә юнәләсең, тормышыңны куркыныч астына куясың, чүлләрнең сыртларын кисеп узасың һәм сәяхәт сәхифәләрен актарасың, ә менә салкын табышың нәкъ күз каршыңда; син аны үзең теләгәнчә, күңелеңә ошаганча җиңел һәм җайлы итеп кулыңа төшерә аласың. Нигә озакка сузарга, йокымсырап торырга? Ни сәбәпле кичектерергә? Ныклап тәвәккәллә дә күтәрел! Мин — синең таянычың, сине тоткарлардык кальга юк; сине туктатырлык киртә юк; сине куарлык көч юк; юлыңа киртә булырлык чагылыш юк; сиңа каршы торырлык дошман юк; синең белән сугышырлык сугышчы юк. Анда җыен этрәк-әләм дә кабахәтләр генә. Андагы байлыклар безгә бирелләчәк һәм алтын-көмеш үз аягы белән киләчәк!» Ул аны (Тимерне) моңа котыртудан, ярсытудан һәм башын әйләндерүдән туктамаган...» Тимер аның сүзләренә колак салган һәм гаскәрләрен төньякка юнәлдергән. Ул барысын да дөрес исәпләгән, аның гаскәрләре җәйләүләрдә үләннәрнең җитеп килү юнәлешендә хәрәкәтләнгән.

Тимерләнг Үргәнечкә яу китергәч,
Колак тонды, ә күзләр булды күрмәс.

Сугыштан купты бар галәмдә туфан,
Агызды, су кебек, җир өстенә кан.
Игенче өйләрен яндырды утта,
Бодай тапталды, туфрак булды ботка.

Яклап илне басты сугышта Туктамыш хан.
Туганнан аерылып калды туышкан.

*Сәйф Сараи*
*«Сөһәйл вә Гөлдерсен». XIV гасыр*

Бу чорда Туктамыш рәтләрендә бердәмлек булмаган. Туктамыш әмирләрне бер-берсенә каршы көрәшмәскә өндәгән: «Без (хәзер) авыр кайгыда, ул (безне) синең теләкләреңнән ныграк борчый, без начар хәлдә, бу безне синең үз бәлаңә караганда ныграк пошындыра, шуңа күрә сабыр ит, ашыктырма һәм тынычлан...

Ләкин бу әмир (аның сүзен тыңламыйча) зур төркем белән алга ыргылган, аның артыннан барлык хыянәтчеләр һәм мөртәтләр, аның Актау атлы барлык нәселе киткән. Ул Рум биләмәләренә юнәлгән, үз кешеләре белән Андрианополь җирләренә җиткән һәм шул урында төпләнеп калган». «Шуның нәтиҗәсендә Туктамыш гаскәре какшаган һәм аның уй-теләкләре төбәлгән нокталарга тимичә узганнар». Тимер белән Идегәй өстенлеккә ирешкәннәр. «Шуннан соң ике гаскәр очрашты, бер-берсенә суктылар, буталышып беттеләр һәм сугыш ялкынына чорналдылар. Дошман дошман белән бәрелеште; кылыч төшәр өчен муеннар сузылды; сөңгеләр тисен өчен күкрәкләр киерелде; йөзләр караңгыланды һәм тузанга батты; сугышчы бүреләр тешләрен ыржайтып улап җибәрделәр; явыз юлбарыслар (сикерергә) әзерләнделәр, көтү арысланнары арт аякларына басып чәйнәштеләр; кеше тиреләре ук каурыйлары белән капланып калтыранды; юлбашчыларның маңгайлары һәм башлыкларның башлары сугыш михрабында догага иелде (табынган кебек) һәм (җиргә) җәелде; тузан купты һәм өерелеп көл күтәрелде; бөтен нәрсә кан дәрьясына күмелде — аксөякләр дә, гади кешеләр дә; тузан өермәсендә уклар очышы шайтан юлбашчыларына ядрә атуга әверелде, һәм көл болытларында кылычлар ялтыравы ханнар һәм солтаннар өстендә ялтыравык балкышка әйләнде. Үлем атлары чабудан һәм бөтерелүдән туктамадылар, отряд арысланнары һаман һөҗүм иттеләр һәм (дошманнарга) ташландылар; тояклардан һавага тузан күтәрелде, үткен кылычлардан дала буйлап кан акты, шул рәвешчә җирләр — алтау, ә күкләр, диңгезләр кебек, сигез булды». Бу сугышта Тимер җиңгән һәм аның гаскәрләре «Азакка кадәр җиттеләр һәм Сарайны, Сарайчыкны, Хаҗитарханны һәм (барлык) бу төбәкләрне җимерделәр. Аның янында Идегәйнең дә дәрәҗәсе күтәрелде. Соңыннан ул, Идегәйнең үзе белән баруын теләп, Сәмәркандка китте». Әмма Идегәй гади фигура түгел, ул — Тимергә йогынты ясый һәм аны үгетли алучы сирәк кешеләрнең берсе. Ул үз туганнарына, сул яктагы ыруларга атчабар җибәреп, аларга туган илгә күчеп китәргә, Тимер куып тота алмасын өчен, беркайда да ике көнгә туктап тормаска кушкан. Аның дружинасы Тимердән качып киткәч, Идегәй, җаен табып, үзе дә Тимердән кача. «Идегәйнең киткәнен белгәч, Тимер, Идегәйнең ялагайланып үзен алдаганлыгын аңлап, үз хатасын төзәтергә теләгән. Ул аңа, килеп чыккан бер эш турында киңәшләшер өчен дип, үз янына кире кайтырга (әмер белән) атчабар җибәргән, әмма атчабар Идегәй алдына килеп басып ни өчен җибәрелгәнен әйткәч, Идегәй аңа һәм аның янындагы әмиргә, үз артыннан баруларын тыеп, болай дигән: «Үз эшегезне үзегез хәл итегез, әфәндегез янына кире кайтыгыз, кулларын ялагыз да әйтегез: безнең аралашу вакыты бетте, моннан соң минем аңа катнашым юк, чөнки мин Аллаһы Тәгаләдән куркам». Бу сүзләр Тимергә барып җиткәч, «ул ачуыннан үз-үзенә кул сала язды һәм (Коръәндә әйтелгәнне) кичерде: (килер) бер көн, һәм «законсыз адәм үз кулларын тешли башлар». Әмма Тимер Идегәйне юкка чыгару дәртенә буйсынмаган, Тимердә аңа каршы яу чыгу теләге тумаган, ул үз биләмәләренә юнәлгән, аннан Сәмәркандка юл тоткан һәм Идегәйне борчымаган. Аның Дәшти Бәркә белән эше шулай тәгәлләнгән. Шуңа күрә: «Тимерне шушы Идегәйдән башка беркем дә алдый да, хәйләдә уздыра да алмаган, ни эше, ни сүзе белән ялгыш юлга кертә дә алмаган, диләр...».

Идегәй Тимердән Алтын Урданы какшату максатында һәм Далада үзенә сәяси һәм хәрби база төзү өчен файдаланган, ул анда Нугай Урдасы дип аталган күчмә дәүләт төзегән.

Камчы тияр муйныңа,
Кан соргылыр куйныңа,
Такыя олы башыңны
Кисәр бугай шул угыл.
Инде мин кеше танымам,
Әгәр кеше танысам,
Котлыкыя би улы
Идегәй ул — Кобогыл!..

*«Идегәй»*

Алтын Урданың бердәмлеген тергезергә тырышкан соңгы хан — Туктамыш булган, ләкин ул җиңелгән һәм уллары белән Киевка, Литва кенәзе Витовт янына качып киткән. 1397 елгы урыс елъязмаларында болай язып куелган: «Тимер Котлык исемле бер хан килде, Туктамыш ханны куып җибәрде, Урдада һәм Сарайда тәхеткә утырды, ә Туктамыш, Витовт белән хәбәрләшеп, Урдадан Киевка качты, ханбикәсе һәм ике улы да үзе белән иде». Татарларны Киев янына, Гроднога, чик буена урнаштырганнар һәм шул көннән Литва һәм Польша гвардиясенең данлы тарихы башланган. Туктамыш улларының берсе — Җәләлетдин — Витовт ягында шартнамә буенча 40 мең татар җайдагы белән Грюнвальд сугышында катнашкан һәм орденны җиңәргә булышкан. Ләкин Витовтның Туктамыш һәм аның уллары ярдәмендә Алтын Урда тәхетен яулап алу теләге гамәлгә ашмаган.

Алтын Урданың көнчыгышында Идегәй идарә иткән, көнбатыш олыслар Олуг Мөхәммәт тирәсендә берләшкәннәр һәм аны хан итеп куйганнар. Ләкин Олуг Мөхәммәт тә тәхеттә озак утыра алмаган, аны да бәреп төшергәннәр. Ул Кырымда, аннан соң Русьта төпләнергә тырышып караган, әмма Сарайга лояль

булган Мәскәү хөкүмәте Олуг Мөхәммәткә һөҗүм иткән. 1437 елның 5 декабрендә урыс-кырым чигендә Белевой янында сугыш була — «урыслар бик күп иде, ә татарлар аз иде, шәһәр янына урыс гаскәрләре килде, татарлар каршы чыгып аларны кырдылар, кайберләре качып котылды, Русьныкылар күп үлде ... урыс гаскәрен җиңделәр, күп бояр һәм кенәзләрне үтерделәр, бөек кенәз кече дружина белән качып китте». Җиңеп чыкса да, Олуг Мөхәммәт алга таба язмышны сынарга теләмәгән һәм үз дәүләтенә нигез салырга һәм Казанны — елъязмачылар сүзе белән әйткәндә, «карт анадан» туган «яшь кызны» — үз дәүләтенең башкаласы итәргә карар кылган. Бу вакытка аерым олыслар чынлыкта мөстәкыйль булганнар. Картада Казан, Әстерхан, Кырым, Себер ханлыклары, Зур Урда һәм Нугай Урдасы барлыкка килгән.

Олуг Мөхәммәт үз сәяси тәҗрибәсе буенча Җүчи Олысын торгызуның өметсезлеген аңлаган. «Казан ханлыгына нигез салуны даһи план дип атарга мөмкин,— дип яза Михаил Худяков,— чөнки Мөхәммәт хан җирле халыкның борынгы культурасы үзенчәлеген яхшы аңлаган һәм, Урта Идел буенда мөселман дәүләтен торгызырга ниятләп, Казанның нык дәүләт булачагын дөрес бәяләгән. Казан ханлыгына нигез салучы Олуг Мөхәммәтнең хәрби таланты һәм оештыру даһилыгы аңа бу дәүләтнең дәрәҗәсен баштан ук тиешле биеклеккә куярга һәм Русиядән тулы өстенлеккә ирешергә мөмкинлек биргән. Ул Русияне Сарай ханлыгыннан бигрәк Казан ханлыгы белән исәпләшергә мәҗбүр иткән. Моның белән Казан татарлары дәүләте Олуг Мөхәммәткә бурычлы». Казан үзенә сәүдәгәрләрне һәм күчеп килүчеләрне җәлеп итеп бик тиз куәт җыйган. «Казан елъязмачысы»: «хан янына төрле илләрдән варварлар җыела башлады, Алтын Урдадан, Әстерханнан, Азуевтан, Кырымнан; бу вакытта Бөек Алтын Урда какшады, Алтын Урда урынына яңа урда — Казан көчәйде һәм ныгыды»,— дип билгеләп үткән.

Зәңгәр күктән тере елан төште,  
Күргән бер кешене ашый башлады,  
Солыр-Казан, һич аямыйча,  
аның башын кисеп ташлады.  
Казан кебек баһадир бәкләрне  
Кемнең дә булса бармы күргәне?

*Еланны җиңгән Казан хөрмәтенә мәдхия. IX — X гасырлар*

Казан белән Мәскәү мөнәсәбәтләре, нигездә, элеккеге Алтын Урда традицияләрен дәвам иткәннәр. Америка тарихчысы Эдвард Кинан болай дип яза: «Сарайда нәтиҗәле сәяси хакимиятнең юкка чыгуы Сарай империясенең элеккеге тәшкилиятләре арасындагы элемтәләрне өзмәгән. Иң әһәмиятле өч үзәктә барлыкка килгән династияләр (Мәскәүдә — Василий I, Бакчасарайда — Хаҗи Гәрәй, Казанда — Олуг Мөхәммәт токымнары) үзара берлекләр тотрыксыз һәм язмышлар үзгәреп торган бу дәвердә еш кына блокларга берләшкәннәр. Берчак барлыкка килеп, алар нык берлек төзегәннәр, ул берлек Далада гына өстенлеккә ирешеп калмаган, ярты гасыр буена Көнбатыш Европа тарихын бик мөһим дәрәҗәдә билгеләп торган».

Тарихи әдәбиятта урыслар белән татарлар арасында, аеруча Алтын Урда таркалганнан соң, кискен каршылык туган дигән ялгыш карашлар киң таралган. Бу Мәскәү тарихчыларына да, Казан тарихчыларына да хас. Чынлыкта исә барысы да күпкә катлаулы. Әлбәттә, сугышлар чыгып торган, әмма башта алар этникара яки дини сәбәпләр нигезендә башланмаган, бу — Алтын Урдадан соңгы киңлектә беренчелек өчен көрәш булган. Мәскәү дә шунда ук басып алуга керешмәгән, аңа үз йогынтысын көчәйтү өчен берлектәшләр кирәк булган, Алтын Урда таркалгач һәм Рязань, Тверь, башка кенәзлекләр мөстәкыйльлеккә ирешкәч бигрәк тә. Шунысы үзенчәлекле, нугай бәге Муса Иван III кә грамотасында : «...минем агам Тимер кенәз сиңа дус һәм абый булган»,— дип исенә төшергән. Иван III, Казан һәм Кырым ханнары белән дуслашып, Зур Урдага каршы булган. Алтын Урдадан соңгы киңлек бер-берсенә уртак мирас белән бәйләнгән көндәшләрнең катлаулы берлегеннән гыйбарәт. 1512 елда Мәскәү белән Казан арасында «мәңгелек солых»ка кул куела. М.Худяков болай дип яза: «Бу ике дәүләтнең мөнәсәбәтләре берлектән гыйбарәт һәм әлеге шартнамә алар арасында солыхны һәм гамәлдәге мөнәсәбәтләрнең даимилеген күздә тоткан,— бу исә берлектәшләрнең хөкүмәттә чит ил сәясәтенең үзгәрешенә китерүе мөмкин булган һәрбер үзгәрешнең үзара килешенеп ясалуы белән тәэмин ителгән. Казан хөкүмәте белән урыс гражданнары арасындагы мөнәсәбәтләргә килгәндә, урыслар ханлыкта иң дустанә держава гражданнары хәлендә, аларның мәнфәгатьләрен якларга тиеш булган җирле дәүләт хакимияте канаты астында яшәгәннәр». Бу килешенүләр сәүдә мәнфәгатьләренә һәм Казан ханлыгында урысларның күплегенә бәйле булган.

Мәскәү белән Казан кайвакыт бер-берсенә каршы сугышканнар, ә кайчакта бергәләп яу чапканнар. Чыганаклардан күренгәнчә, Олуг Мөхәммәт уллары Касыйм һәм Якуп Василий Темный гаскәрләрендә хезмәт иткәннәр. Касыйм Ока елгасы буендагы Мишәр шәһәрчегендә — Касыйм ханлыгы дип аталган җирдә удел кенәзе буларак Мәскәү дәүләтендә калган. Казанда туган Кырым шаһзадәсе Габдулла Латыйф кулына Звенигород тапшырылган. Ә аның абыйсы Мөхәммәт Әмин Кашира белән идарә иткән, соңрак аңа Серпухов

һәм Хатуньны да китереп кушканнар. 1500 елгы Литва сугышында ул бөтен урыс армиясенең башлыгы булган. 1502 елда Мөхәммәт Әмин Казан ханы итеп сайланган, ләкин, һич көтелмәгәнчә, урысларга каршы сәясәт алып бара башлаган. Ул елларда Нурсолтан ханбикә шактый мөһим роль уйнаган. Аның балалары — Габдулла Латыйф һәм Мөхәммәт Әмин — Мәскәү кенәзлегендә һәм Казанда торганнар, ханбикә үзе Кырымда яшәгән. Нурсолтанга өчяклы мөнәсәбәтләрдә бик күп каршылыкларны җайларга туры килгән, ул үзен шактый оста дипломат итеп таныткан.

Мәскәүнең ныгуы татар этник үзаңының какшавы җирлегендә барган. Идегәй яклылар нугайлар дип атала башлаган. 1428 елда Урдадан Төмән аерылып чыккан, анда Әбелхәер хан һәм аның олысы «үзбәкләр» исемен алганнар. Якынча 1438 елда Кырым һәм Казан аерылып чыккан — Кырым, Казан, соңрак Әстерхан татарлары барлыкка килгән. Гомумтатар үзаңы һәм теләктәшлеге көндәшлек һәм дошманлыкка алмаштырылган. 1480 елда Зур Урданың җимерелүе — урыслар түгел, нугайлар һәм кырымнар эше. Сарай белән берлекне барысыннан да озаграк нәкъ менә Мәскәү саклаган, гәрчә ясакны даими рәвештә түләмәсә дә. Халыктан татарларга дип җыела торган акча Мәскәү кенәзенең казнасында калып барган.

Мәскәүдә баскынчылык теләге тиз генә тумаган. Казан җиренең бер өлешен тартып алып «Василь-шәһәр» төзергә уйлаган вакытта, Мәскәүдә күпләр моны хупламаган, чөнки тынычлык сугышка караганда кадерлерәк булган. Әмма хөкүмәт руханилар тарафыннан хуплау тапкан. Митрополит Даниил болай дигән: «Без шул шәһәр аркылы Казанның бөтен җирен алачакбыз». Мәскәүнең Казанда үз тарафдарлары булган. Казанның эчке сәясәте төрле партияләр — Мәскәү, Кырым, Нугай төркемнәре арасында даими көрәштән гыйбарәт, бередә Казанның үз төркеме генә җитмәгән. Шуңа күрә, Олуг Мөхәммәт үлгәннән соң, ханнар тиз алышынып торган. Сарай түнтәрелешләре ясау кәсепкә әйләнгән.

Казанның көчсез һәм сәләтсез ханнарының озын рәтендә Шаһгали фигурасы аерым тора, мондый фигура тарихның кризислы чорларында гына барлыкка килергә мөмкин, ул чакта батырлык риваятьләрдә генә калган, ә сатылуны уйланылган сәясәт дип атаганнар.

Шаһгали Мәскәүгә бик тырышып хезмәт иткән. Аның Василий III нең дусты дигән даны таралган Василий аңа ихтирам күрсәткән һәм Казан тәхетенә һәрвакыт аны тәкъдим иткән. Әмма Казанда Шаһгалине яратмаганнар һәм сайлап кую белән шунда ук төшергәннәр дә. Рим императоры илчесе Сигизмунд Герберштейн аны кабул итү мәҗлесләрендә күргән һәм «Мәскәү иле турындагы язмалар»ында бу турыда истәлек язып калдырган: «Үз гражданнарының аңа карата бөек нәфрәтен аның ямьсезлеге һәм зәгыйфьлеге арттырып тора иде, чөнки ул — бүлтәеп чыккан корсаклы, сирәк сакаллы кеше, йөзендә хатын-кыз чалымнары бар иде, болар барысы да аның сугышка бер тамчы да сәләтле түгеллеген күрсәтә иде». Урыс елъязмачысы мәсхәрәле төстә искәртеп калдырган: «Татарлар шундый патшаны үзләре мыскыллар һәм көләр өчен махсус сайлаганнар».

Шаһгали 1523 елда урыс гаскәре Казанны алырга җыенганда аның башында торган. «Казан тәхетенә дәгъвачы сыйфатында,— дип яза Михаил Худяков,— ул урысларның Казанга каршы походларында катнашкан: 1537 елда Шаһгали урыс армиясенең Владимирдагы штабында булган, 1540 елда ул Казан кешеләренә Муром юнәлешендә каршы чыккан, 1541 елда ул урыс гаскәрләренең Владимирдагы җыелу пунктында кабат булган». Соңрак, 1549 елда, ул «Казан шәһәре янында 7 көн торучылар» белән бергә булган. 1550 елда Шаһгали белән урысларга хезмәт итүче Әстерхан шаһзадәсе Ядегәр Казанны һөҗүм итеп алырга тырышып караганнар. Казанны яулап алуны оештыручылар арасында урыслар да, татарлар да тигез санда булганнар.

Шаһгали Мәскәү тарафыннан хан тәхетенә беренче тапкыр 13 яшендә Касыйм шаһзадәсе буларак тәкъдим ителгән. Ул идарә иткәндә Казанда урысларның зарарлы йогынтысы ахыр чиккә җиткән. Асылда ханлыкка бөтен эшләргә дә тыгыла торган урыс илчесе идарә иткән. Ике ел эчендә Шаһгали бөтен кешедә үзенә каршылык хисе тудырган һәм 1521 елда Кырым шаһзадәсе Сәхиб ярдәмендә түнтәрелеш ясалган. Елъязмачылар белдергәнчә, түнтәрелеш вакытында хан гвардиясендәге 5 000 касыйм татары һәм 1 000 урыс сугышчысы һәлак булган. Шаһгали үзенең дусты Василий III янына качкан.

1553 елның гыйнварында Шаһгали Илчеләр приказына күрсәтмичә генә Казан белән хат алышканы өчен кулга алынган. Аны гаиләсе һәм якыннары белән бергә төрле төрмәләргә сөргәннәр. Урыс елъязмачысы аларның хәлен тасвирлап калдырган. Псковта «шул ук (1535) елда, июнь аенда, 26 нчы көндә татар ханы Шаһгалине һәм аның 73 кешесен төрмәгә утырттылар, Бөек елгадан Бурков костры (манарасы) янында, Урта шәһәрдә, үлемгә дип утырттылар, шул исәптән кечкенә җиде баласын да көне-төне изалап чыгарып ташладылар, төрмәдә исән калган сигезен күп көннәр ашатмадылар-эчертмәделәр, үтерделәр; ә хатыннарын башка төрмәгә, җиңелрәк һәм якынрак төрмәгә — Трупех капкасы, Изге Василий янына тауга утырттылар». «Шул ук елда татар хатыннарын чукындырдылар» һәм урысларга кияүгә биргәннәр. Башка төрмәләрдә дә шул ук хәл булган. Шаһгали кешеләреннән Хәсән атлы бер генә татарны исән калдырганнар, чөнки ул чукынырга риза булган.

Ләкин Казан ханы Җангали үтерелгәч, Казан тәхетенә Русия белән берлек яклы партия тарафыннан тәкъдим ителгән бердәнбер кандидат — Шаһгали булган. Казаннан Мәскәүгә күчеп киткән кешеләр болай дип белдергәннәр: «Патша безгә игътибар күрсәтеп, Шаһгалигә ачуын онытып, аңа Мәскәүгә килергә кушсын иде, Шаһгали бөек патша янына Мәскәүгә килсә, без Казандагы киңәшчеләребез белән берләшер идек һәм Кырым ханы Казанга килә алмас иде». Елена Глинская хөкүмәте Шаһгалине азат итүне мәгъкуль санаган.

1546 елда Шаһгали яңадан хан булган һәм шартнамә буенча Казанга чит ил гарнизонын кертмәскә, элеккеге үпкәләр өчен эзәрлекләмәскә сүз биргән, ә Казан кешеләре исә аңа шәхес иминлеге гарантияләгәннәр. 13 июньдә ул тәхеткә утырган һәм анда тәгәл бер ай торган. Сафа Гәрәй Нугай Урдасы белән шартнамә төзүгә ирешеп, хәрби отряд алып килгән һәм үзе инде бер тапкыр утырган Казан тәхетен кире үзенә кайтарган.

1551 елның 16 августында Шаһгали Казан тәхетенә кабат утырган, өстәвенә шундый шарт белән: ханлык ике өлешкә бүленергә тиеш — Зөядән торып идарә ителүче уңъяк яр һәм Казан идарәсенә калучы калган өлеш.

Мәскәү 1552 елга кадәр Казанны тыныч юл белән, ягъни үзе идарәчесен куеп, үзенә кушарга тырышкан. 1552 елның 6 мартында Шаһгали хан урыс илчесенә тәхеттән ваз кичәргә ризалыгын белдергән һәм кальгадан чыгып киткән. Казан идарәчесе итеп Зөя воеводасы Микулинский куелган. 7 мартта хәрби хезмәттәге казанлыларны ант иттергәннәр, ә 9 мартта идарәче Зөядән Казанга килергә чыккан. Ул Бишбалта бистәсенә җиткәч, аны озатып баручы өч татар: Ислам кенәз, Күбек кенәз һәм Нарыков морза алдарак барырга рөхсәт сораганнар. Алар, шәһәргә алдан кереп, кальга капкаларын япканнар һәм рәхимсез суеш булачак дип, ялган хәбәр таратканнар. Шәһәр кешеләренең күбесе коралланa башлаган. Микулинский бикле капкалар янына килеп җиткән һәм сөйләшүләр башларга тырышып караган, ләкин кире борылып Зөягә кайтып китәргә мәҗбүр булган. «Берләшү барып чыкмады һәм Казан кешеләренә моның өчен коточкыч корбаннар бирергә туры килде»,— дип яза М.Худяков. Мәскәү сугыш хәрәкәтләренә күчкән һәм Казан җирен дөньяда тиңе булмаган кансызлык күрсәтеп үзенә буйсындырган. Казанны алганнан соң, Явыз Иван Нугай бәгенә «Казан сөенечен әйтергә» («казанскои сеунчь сказати») атчабар җибәргән. «Ходай безгә рәхимлек күрсәтте,— дип язган патша,— Казанны барлык кешеләре белән безнең кулга бирде». Аның бу хатны берлектәшенә язганы ачык күренеп тора. Казанны алганнан соң халык «җәннәт җирләренә» качкан, «Төньяк-Көнчыгыш Русь бөтенләй буш калды».

Сөембикә ханбикә Нугай нәселеннән булса да, нугайларны Казан хәлләре аз борчыган. Мәскәүгә карата икътисади мәнфәгать дини һәм төрки теләктәшлектән өстенрәк булган. Әмма нугайлар Казанны буйсындыру вакыйгасының сәяси һәм икътисади нәтиҗәләрен исәпкә алып бетермәгәннәр. Казанны алу ул — бер күренеш кенә түгел, Алтын Урдадан соңгы киңлекнең җимерелүен һәм башка ханлыклар язмышына тәэсир итүче яңа халыкара мөнәсәбәтләр урнашуын аңлатучы факт булган. Мәскәү белән дуслык Нугай Урдасының үзен дә коткарып кала алмаган.

Сөембикәнең атасы, Казанны һәм Әстерханны яклау тарафдары Йосыф бәй белән аның абыйсы, Мәскәү яклы, Мәскәүгә каршы хәрби экспедицияләрне өзүче Исмәгыйль арасындагы киеренкелек ахыр чиккә җиткән. Һәм чуалыш — болгак башланган. Исмәгыйльнең урысларга Әстерханны алырга ярдәм итәргә җыенуы Йосыф бәйне чыгырыннан чыгарган. Үзара талаш Йосыфны үтерү һәм Исмәгыйльне бәй итеп кую белән тәгәлләнгән. Мәскәү тантана иткән, ә дала цивилизациясе үлем белән тартышкан.

Эчке талашлар икътисадның җимерелүенә китергән һәм далада ачлык башланган. Урыс илчесе патшага язган: «Ә нугайлар, патшам, бетә баралар, аларда яхшы (ягъни мул тормышлы) кешеләр аз, нугайлар, патшам, гадәттән тыш ач һәм җәяүле. Ачлыктан кеше күпләп үлә... Аларның җире, патшам, әрәм була, бербереен талыйлар... Аларны зур мохтаҗлык җәфалый, Нугайда кешеләр ач...». Исмәгыйль ярдәм сорап Мәскәүгә мөрәҗәгать иткән, ләкин җавап алмаган.

Нугайлар, үзләренең берлектәше — урыс патшасының ярдәменә өметләнеп, стихияле төстә Әстерханга юнәлгәннәр. Нәкъ шушы вакытта шәһәрдә булган Дженкинсон болай дип дәлилли: «Ләкин аларны начар кабул иттеләр һәм ярдәм аз булды: күпчелеге ачтан үлде; аларның мәетләре, хайваннарныкы шикелле, күмелмичә, утрау буйлап өем-өем аунап ятты». Дженкинсон фикеренчә, Әстерхан хакимияте нугайларның бетеп баруына сөенеп караган. «Исән калганнарның күбесен урыслар коллыкка саттылар, ә калганнарын куып җибәрделәр...».

Русиядә ачлык турында белгәннәр, әмма аны Ходай җәзасы дип кабул иткәннәр. Кенәз Курбский гомуми фикерне болай тәгъбирләгән: «Бу үләт Нугай Урдасына Ходайдан Идел буе татарларын бетерер өчен җибәрелгән, ул аларга казалар җибәрде: «Алар өстенә коточкыч салкын кыш китерде, аларның барлык мал-туарлары: ат көтүләре дә, башка терлекләре дә үлеп бетте, җәйгә нугайлар үзләре дә беттеләр, чөнки алар үзләренең төрле-төрле терлек көтүләренең сөте белән туеналар иде, ә икмәк хәзер анда телгә дә алын-

мый, исән калганнарда исә Ходай ачуы ныграк чагылды, алар, ашарга эзләп, Перекоп Урдасына килеп җиттеләр. Ходай аларны анда болай җәзалады: кояш кызуыннан корылык китерде, елгалар агып торса да, алардан су алып булмады, җирне 3 сажин тирәнлектә казысалар да су күп чыкмады. Шул рәвешчә, Идел аръягында Исмәгыйль халкы бик аз калды, көчкә-көчкә генә 5 мең гаскәри булыр, ә бит аларның саны диңгездәге ком бөртекләре кадәр иде». Бетеп баручы «басурманнар»ның хәленә керүче булмаган. Исмәгыйль үзе урыс патшасына зарланган: «Синең хакка барча кешеләрдән аерылып калдым. Безнең баштагы дүрт ханның балалары, безнең туганнарыбыз, миннән аерылдылар, чөнки мин синнән аерылмадым... Атам өлкән кенәз Йосыф һәм абыем бар иде, аннан да синең хакка аерылдым, нәселемнән дә синең хакка аерылдым, улларымнан да синең хакка аерылдым. Миңа: «Син урыс булырсың!» — диделәр, шуңа күрә дә миннән аерылдылар. Мине дошман итеп күрделәр». Ул хәтта «үз-үзенә кул салырга теләгән» дигән сүзләр дә йөргән.

Исмәгыйль бәйне дошманнары гына түгел, көрәштәшләре дә ташлап киткәннәр, хәтта ике улы да Кырымга, туганнары Дәүләт Гәрәйгә күчеп киткәннәр. Анда аларны талаганнар һәм алар көчкә качып котылганнар, өстәвенә берсе Дон казакларына әсирлеккә төшкән. Ахыр чиктә алар аталары янына кайтканнар, үзләренең кул астындагы күпсанлы кешеләрдән үзләре белән бары унбише генә кире кайткан. С.М.Соловьев болай дип язган: «Идел буе далаларында күчмәләр бер-берсен шулай суеп бетергәннәр һәм Мәскәү дәүләтенә тулы тантана тәэмин иткәннәр».

Нугай Урдасы беркайда да — Кырымда да, Урта Азиядә дә, казах ханында да, хәтта тугры «берлектәше» Мәскәүдә дә яклау тапмаган. А.Беннигсен һәм Ш.Лемерсье-Келькеже Мәскәү-Нугай мөнәсәбәтләрен түбәндәгечә бәяләгәннәр: «Урысларның төп союздашы, Мәскәү җиңүенә әһәмиятле өлеш керткән Исмәгыйль морза, аның иң тәүге корбаннарыннан берсе булган, ул яңа урыс «патшалыкларыннан» берниди матди файда да, өстәмә җирләр дә алмаган. Ә бит нугайлар ярдәменнән башка ни Әстерхан, ни Себер ханлыкларын яулап алу да, өстәвенә Кавказга чыгу да мөмкин булмаган.

Казаклар, вазгыятьтән файдаланып, Мәскәү ризалыгы белән нугайларны үтереп бетергәннәр, хәтта аларның башкаласы Сарайчыкны да җимереп ташлаганнар. Явыз Иван аларга теләктәш булган, гәрчә нугайлар каршында: «Үзегезгә үк мәгълүм: елгыр адәмнәр кайда гына юк? Кырда казаклар күп йөри: Казан, Азов кешеләре, кырымнар һәм башка шук казаклар, безнең украин казаклары да аларга кушылып йөриләр. Бу кешеләр сезнең өчен юлбасарлар икән, безнең өчен дә нәкъ шулай ук. Аларны беркем дә явызлыкка өйрәтми, алар үзләре явызлык кылалар да кире үз җирләренә таралалар». Казаклар күчмә культураны тәмам юкка чыгарганнар, гәрчә үзләре, этнография элементы буларак, аның ачык билгеләрен саклап калсалар да. Утрак цивилизация Мәскәү сурәтенә кереп тантана иткән.

Әй соргавыл, соргавыл,
Сыргыең бар, соргавыл,
Саркытың юк, соргавыл!
Кузалак арба йөрмәстәй
Каргаулымы иде илегез?
Тәрәкле арба йөрмәстәй
Тиргәүлеме иде илегез?
Гарип бер юлчы килмәстәй
Хәерсезме иде илегез?
Каласын күрдем анда,
Йортын күрдем юлда,
Тияге монда, үзе кайда?
Җир кемнеке, тел кемнеке,
Дин кемнеке, әйт! — диде.

*«Идегәй»*

Алтын Урда сәясәте дөнья тарихының бер өлеше булса,— урыс кенәзлекләре тарихы — татар тарихының бер өлеше. Бәлки, моны тану авырдыр, әмма бу нәкъ шулай. Һәм биредә үпкәләр җир юк, татарның соңгы дүрт йөз еллык тарихы Русия тарихының бер өлеше булуы да шулай ук. Урыслар Алтын Урда аркасында дөньяви процессларга кушылганнар, бу исә бөек Русия төзүгә алшартлар тудырган.

Вакытлар узар, идеологик кабыклар кубып төшәр һәм Алтын Урда мирасына күп халыклар дәгъва итәр. Алтын Урда культурасы кешелек тарихында мөстәкыйль һәм гаять әһәмиятле урын тота. Ул Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында чын күпер булган. Алтын Урда культурасы күп кенә төрки һәм башка халыкларның урта гасырлардагы казанышларын үзенә сеңдергән. Бик яхшы финанс системасына корылган камил икътисад бик зур территориягә күзәтчелек итәргә, анда иминлек тәэмин итәргә мөмкинлек биргән һәм ул заманнар өчен хыялый дәрәҗәдә булган элемтә һәм идарә, бик шәп хәрби сәнгать, фән, әдәбият, төзелеш сәнгате һәм башкалар — болар барысы да Алтын Урданың урта гасырларда иң югары дәрәҗәгә

ирешкән мөстәкыйль культурасы хакында сөйли. Кешелек инде бүген үк Чыңгыз ханның дөнья тарихындагы роленә башкача карый, килер вакыт — һәм Алтын Урда дәвере үзенә лаек рәвештә бәяләнер.

Төрки цивилизация үсешенә ике бөек дәүләт хәлиткеч йогынты ясый — Госман империясе һәм Алтын Урда. Госман империясе төрки тарихның менә дигән сәхифәсе генә түгел, ул, XX гасырга кадәр дөньяви процессларга йогынты ясап, ислам дөньясының үзәге булып торган. Татарлар исә, Алтын Урдадан соңгы ханлыклар беткәч, физик һәм мәдәни яктан исән калу вазгыятендә булып чыкканнар.

Татарларның соңгы терәге — Кырым ханлыгы булган, ул күбесенчә Оттоман империясенә таянган. Кырым җимерелгәч, татар факторы дөнья аренасыннан юкка чыккан. Алтын Урда кыйпылчыклары булып Казах, Хива һәм башка ханлыклар калган, әмма алар үз этник чалымнарын — үз исемнәрен генә түгел, үз мәдәниятләрен дә булдырганнар.

Кайда Ибраһим яки Әдһәм бөек?
(Солтан иде, яшәде ярлы кебек.)

Кайда Чыңгыз?! Кайда ул?! Бит ул да юк!
(Язмышы бу залимнең дә бит шул ук.)

Барсы да — бу дөньяны тоткан кеше.
Мондый булырмы аларның соңгы эше:

Яттылар җирдә кәфенгә чолганып,
Тәннәре үз каннарына болганып,

Калдырып ятларга бар байлыкларын,
Тәхте-бәхтен, мәмләкәтләрен — барын.

Бу канун: килгәч китәргә син тиеш.
(Бәс, тырыш эшләргә һәрчак изге эш.)

Сак кына бас, җиргә басканда — кара!
Туфрак ул чергән үлекләрдән тора.

Һәр адым куйганың җирнең өстенә,
Басмага мөмкин берәүнең битенә.

*Х.Кятиб*
*«Җөмҗөмә солтан». 1368 —1369*

## «Изү»

*Сарай дигән калада*
*Дүрт дәрваза бар икән,*
*Икәве бикле булганда,*
*Икәвен ачык куйдырды.*
*Береннән килгән кәрваны*
*Береннән чыгып бетә алмый,*
*Боҗрасы бөтен алкадай*
*Боралып киткән мал булды.*
*...Ил казнасы бай булды.*
*Биләгәне кол булды,*
*Әйләгәне мал булды;*
*Җәеп салса көмешен —*
*Җәйрәп яткан күл булды;*
*Өеп салса алтынын —*
*Әлдермештәй тау булды.*
*Ашаган казы ял булды,*
*Эчкәне сары бал булды.*

«Идегәй»

В.В.Каргалов «Урда изүенең азагы» дигән китабында (1980) шуны дәлилләгән: «изү» сүзен беренче тапкыр король Стафан Баториянең статс-секретаре Рейнгольд Гейденштейн «Мәскәү сугышы турында язмалар»да кулланган. Аннан бу төшенчәне күренекле француз тарихчысы Де Ту эләктереп алган. Шуннан соң әлеге төшенчә мәшһүрләшеп киткән. Урыс кенәзләре исә үзләренең «изү» астында булганнарын белми-сизми дә калганнар. Шул рәвешчә, бу термин XVI гасырда гына барлыкка килгән һәм аңа идеологик вазифа йөкләнгән. Ул бүген дә әнә шул акыллы немец уйлап чыгарган вазифаны башкара.

Татар-монгол «изүе» турындагы стереотиплар шулкадәр көчле ки, ул тарихи чор турында теләсә нинди уйдырмалар сөйләргә мөмкин һәм кешеләр моңа ышаначаклар, әмма «изү»нең булмаганлыгын бик азлар гына кабул итәчәк — ничек инде булмасын, булган лабаса! Гадәти мантыйк әнә шундый.

Чынлыкта исә «изү» — гаять зур әкият һәм аны Русия дәүләте бар куәткә хуплый. Хәер, болай әйтүләре дә бар: ябырылу булган, басып алу булган, димәк, изү дә булган!

Татар-монголлар барлыкка килгәнче Русь бер-береннән читләшә барып, үз эчләрендә таркала торган күп кенә кенәзлекләрдән гыйбарәт булган. 1097 елда Любечта кенәзлекләр корылтае узган, анда «һәркем үз җирен тота» дип карар кылынган. Кенәзләр яңа принципны какшамас төстә үтәргә ант иткәннәр, шуны дәлилләп тәре дә үпкәннәр. Шул рәвешчә Русь яңа сәяси оешмага — бәйсез дәүләтләр конфедерациясенә әверелгән. Тора-бара Төньяк-Көнчыгыш Русь һәм көньяк-көнбатыш җирләр (Волынь, Киевщина һәм Галиция), Чернигов кенәзлеге, Смоленск, Туров-Пин җире аерылып чыкканнар, Новгород тулы бәйсезлек алган. Ни дәүләттә, ни чиркәүдә бердәмлек булмаган, һәркайда үзара сугыш барган. 1216 елда Ростов-Суздаль җирендә «Уллар — аталарына, аталар — улларына, туган — туганына, коллар — хуҗаларына, хуҗалар — колларына каршы чыкты» дип яза елъязмачы. Төньяк җирләрдән Владимир Мономах вакытында ук аерылып чыккан Муром-Рязань җирләре үз чиратларында үзләре үк төрле кенәзлекләргә таркалганнар. Нәтиҗәдә XIII гасыр башына Чернигов-төньяк җирләрендә Козельск, Курск, Трубчев, Снов, Рыль, Лопасна, Вщиж, Новгород-төньяк, Путивль, Стародуб, Дебрян, Караваев һәм башка кенәзләрнең уделлары мыжлап торган. Алар бер-берсенә каршы сугышканнар.

Шул рәвешчә, татар-монголларга кадәр йөз ел элек аерым кенәзлекләр бер-берсен юкка чыгару белән шөгыльләнгәннәр, өстәвенә бу гамәлнең максатлары да аңлашылмый. «Кыргыйлык һәм туганның туганга каршы явызлануы урыс хакимнәре, бертуганнар яки туганнан туганнар, абыйлар, энеләр тирәлегендә артык еш булып торган. Моның коточкычлыгын Александр Невский образы гына бераз каплап торган,— дип яза В.О.Ключевский.— Әгәр тормыш тулысынча алар ихтыярында булса, алар бөтен Русьны бер-берсенә бәйләнмәгән, үзара мәңге дошман булган удел корамаларына өзгәләп бетерерләр иде... Хан нәфрәте сугыш чукмарларын тыеп торган, ханның рәхимлеге, ягъни аның ихтыяры белән бөлдергеч үзара сугыш күп тапкырлар кисәтелгән яки туктатылган. Хан хакимияте Всеволод III нәселенең ил эшләрен бутап, бик белеп төйнәгән төеннәрен кисеп атучы тупас татар пычагы булган. Урыс елъязмачылары «поганый агарян»нарны Ходайның гөнаһлыларны аңга китереп тәүбә юлына бастыручы җәза таягы (батог) дип юкка гына атамаганнар». Бөтен дәреслекләр һич үзгәртмичә яза торган «Урыс җиренең һәлакәте» татар-монгол явы нәтиҗәсе була алмаган, чөнки ул Батый хан барлыкка килгәнче үк, аннан күпкә элегрәк тарихи факт булган инде.

«Ябырылу» башта Русьны басып алуны күздә тотмаган. Болгарны тар-мар иткәннән соң татар-монгол гаскәрләре Иделне кичкәннәр дә ике канатка бүленгәннәр. Берсе — Мүнкә җитәкчелегендә — кыпчакларны куа киткән. Кыпчакларны Венгрия короле үз канаты астына алган. Икенчесе — Батый хан җитәкчелегендә — кыпчакларны урыс җирләре ягыннан камап алган. Батый хан үз гаскәрен урыс кенәзлекләре җирләре аша үткәрүне, азык-төлек һәм атлар бирүне таләп иткән. Әмма кенәзләрнең күпчелеге баш тарткан. Рязань кенәзләре, мәсәлән, болай дип җавап биргәннәр: «Безне үтерсәгез, бар да сезнеке булыр». Нәтиҗәдә Батый хан Рязаньны, Владимирны, төньяк-көнчыгыштагы Торжокны, Козельскины, Көньяк Переяславльне, Черниговны, Киевны, көньяктагы Колодяжин һәм Каменецны, көньяк-көнчыгыштагы Галичны һәм Владимир-на-Волыни шәһәрләрен басып алган. Татарлар яулап алган дип белдерелгән калган унбер шәһәргә килгәндә исә, аларның татарлардан зыян күрүе турында дәлилләр юк. Н.Н.Воронин Ярославль, Ростов, Углич, Кострома, Төньяк Переяславль, Тверь һәм «башка шәһәрләр» сугышмыйча гына бирелгәннәр һәм татарлар тарафыннан җимерелмәгәннәр дип саный. Бөек Владимир кенәзлегенең төньяк өлеше исә вакытында уздырылган сөйләшүләр һәм һөҗүм итүче татар-монгол армиясенә азык-төлек һәм атлар биреп капитуляция ясау аркасында исән-имин калган. Ул заманда барысы өч йөзгә якын урыс шәһәре булган.

Киев җирендә аны яулап алынганнан соң биш ел узгач сәяхәт иткән Плано Карпини болай ди: «Киевтан «бернәрсә дә калмаган диярлек, хәзерге вакытта (1245 елда) анда нибары 200 йорт исәпләнә, ә халкын тулысынча коллыкта яшәтәләр». Плано Карпининың шушы сүзләрен һәрдаим өземтә итеп китерәләр. Киевны алуны ачык тасвирлаучы Ипатьев елъязмасында нинди дә булса биналарны җимерү, хәтта халыкны кыйнау турында да бернинди мәгълүмат юк. Киевны яулау турындагы Лаврентьев елъязмасы бу хакта өстән-өстән генә язган, ә Новгород елъязмасында бөтенләй бернәрсә дә юк. Бу гаҗәп түгел, чөнки Киевны татарларга кадәр урыслар үзләре үк өч тапкыр җимергәннәр. С.Ф.Платонов сүзләре буенча, «татарларның килүе аңа ахыргы һөҗүм булган». Ул инде болай да хәрабә хәлендә яшәгән. «Батыйга кадәр, төгәлрәге 1169 елда, Киевны Андрей Боголюбский бөлдергән, ул үз сугышчыларына Русь башкаласын өч көн таларга ирек биргән, гадәттә, моңа бары тик чит шәһәрләр генә дучар ителгәннәр. 1203 елда кенәз Рюрик Ростиславич Смоленский да Киевта шулай ук кыланган, аңа «Игорь полкы турында сүз»нең мәгълүм герое —

кенәз Игорь Святославич булышкан. Шулай итеп, Батыйга Киевтан әллә нәрсә калмаган да...». Батый хан Киев янына килеп җиткәч, кенәз качкан, чөнки шәһәрне яклап сугышырлык кеше калмаган. Бу шәһәрдә татарлар яулап алырлык һәм җимерерлек бернәрсә дә булмаган инде.

Киев Русе XII гасырның икенче яртысыннан какшый башлаган, ул чакта «варяглардан грекларга» сәүдә юлы шведлар, немецлар, литвалар ягыннан тәре походлары нәтиҗәсендә үз әһәмиятен югалткан. Татар ябырылуы Русьның бетүгә йөз тотуына һәм артка калганлыгына сәбәп була алмаган. Петр Савицкий раславынча, «XIII гасыр башындагы Русьта бөтенләй беткәнлек күренеше хөкем сөрә: Көнбатыш белән чагыштырганда, масштаблар аермасы — ун кат, йөз кат. Һәм бу татар изүе нәтиҗәсе түгел, татар изүенә кадәр үк чып-чын «артталык»!»

Новгород республикасына, Полоцк, Смоленск һәм Туров-Пинск кенәзлекләренә татарлар кагылмаганнар. Рязань зур зыян күргән, ләкин татарлардан бигрәк Суздаль кешеләреннән. Татар-монголлар үзләреннән соң гарнизоннар калдырмаганнар, шуңа күрә алар киткәч тормыш гадәти эзенә төшкән. Зыян күргән шәһәрләр бик тиз яңадан төзелгәннәр, тормыш элеккечә дәвам иткән. «Рязаньның бөлүе турында хикәят» ябырылу нәтиҗәләрен болай тасвирлый: «Игелекле бөек кенәз Ингварь Ингваревич... үз атасы урынына утырды... Һәм Рязань җирен яңартты, чиркәүләр төзеде, монастырьлар корды, килгәннәрне урнаштырды, кешеләрне җыйды. Христианнарга шатлык килде, Ходай аларны ... явыз Батый патшадан коткарды». Археологик казынулар Рязаньның тиз торгызылуы турындагы әлеге дәлилне исбатлыйлар.

Плано Карпини, Рәшидетдин һәм Ибне әл-Әсири раславынча, татарлар тәҗрибәле һөнәрчеләрне һәм осталарны үзләре белән алып киткәннәр, бу өлешчә хак нәрсә. Әмма өлешчә генә, чөнки урыс кенәзлекләрендә тулаем алганда һөнәрчелекнең бөлгенлеккә төшүе күзәтелмәгән. Авыл хуҗалыгына килгәндә, Б.А.Рыбаков күрсәткәнчә, татарлар крестьяннарга карата сак эш иткәннәр, Ипатьев елъязмасы сүзләре белән әйткәндә, «бодай һәм тары үстерерләр» дип аларга кагылмаганнар. Батый һөҗүменнән соң урыс кенәзлекләрендә беркем дә ясак түләмәгән, чөнки татар гаскәрләре урыс җирләре аша узып кына киткәннәр. Ясакны 20 елдан соң гына түли башлаганнар.

Тарихи әдәбиятта татарлар рәхимсезлегенең ачык һәм бәхәссез бер үрнәге һәрвакыт очрап тора — нигезенә кадәр җимерелгән Козельск шәһәре. Кайбер авторлар тасвирлавынча, имеш, ул татар-монгол явына каршылыкның үзәгенә әверелгән диярлек. Бу — аерым очрак, чөнки ул «явыз шәһәрләр»дән исәпләнгән, ягъни анда илчеләрне үтергәннәр, ә бу Чыңгыз хан «Яса»сы буенча иң зур гөнаһ булган һәм моның белән килешергә була, мөгаен. Татар-монголлар мондый гамәл өчен хакимнәр генә түгел, бөтен шәһәр җаваплы дип исәпләгәннәр, димәк, ул юкка чыгарылырга тиеш һәм алар моны башкарганнар да. Козельскины камалышта тотканда, бер генә урыс кенәзе дә ярдәмгә килмәгән. Гәрчә нәкъ менә шушы вакытта Ярослав Всеволодович Литвага һөҗүм итеп уңышка ирешкән.

Ябырылу тарихи язмаларда тасвирланганча ук коточкыч булмаган. «Татарлар ябырылуының турыдан-туры нәтиҗәләре нинди булган? — дип сорый Д.Феннел.— Урыс тарихының башлангыч чорына хас булганча, язма чыганаклар да татарлар китергән сәяси, мәдәни яки икътисади зыян турында нинди дә булса нигезле нәтиҗә ясарлык мәгълүмат искиткеч аз. Дружиначылар яки гражданнар арасында югалтулар саны күрсәтелми, без күпме кеше әсирлеккә алынганын да белмибез. Ул замандагы елъязмачылар, сәяхәтчеләр һәм тарихчылар хәтта арттырылган саннар күрсәтүдән дә катгый рәвештә баш тарталар: йә алар Киев очрагындагы кебек бер сүз дә язмыйлар, йә укучыларны пешмәгән гиперболалар белән куркыталар... Физик яктан юк итү һәм мәдәни кысрыклау турында археологик мәгълүматлар шулкадәр аз ки, алар нигезендә һөҗүмнән соң урыс шәһәрләре һәм авыллары торышы турында реаль картина булдыру мөмкин түгел».

Авыр «татар ясагы» турында сүзләр дә бик күпкә арттырылган. В.В.Кожинов болай яза: «П.Н.Павловның «Алтын Урдага урыс ясагы мәсьәләсенә» дигән бик әһәмиятле, ләкин табуы бик кыен булган бер язмасына игътибар иттем. Ул «Красноярск педагогия институтының фәнни язмалары»нда 1958 елда басылган. Бу әлеге мәсьәлә җитди һәм төгәл куелган бердәнбер хезмәттер, мөгаен. Һәм бу язмадан ачыклана: уртача еллык ясак, хәзерге заман исәбенә күчергәндә, җан башына бары тик 1 — 2 сум гына! Ул, ясак җыючы урыс кенәзләренең казнасына шактый сукса да, халык өчен авыр булмаган. Ә менә хәтта шул ук вакытта Иван Калита улы Симеон Гордый ясак түләгән кадәр үк сумманы, ярдәм йөзеннән, Константинополь патриархиясенә үзе теләп биреп барган». Алай гына да түгел, татарлар ябырылуы вакытында урыслар арасында кенәзләр, боярлар, урядниклар изүеннән, бетмәс-төкәнмәс үзара сугышлардан, кенәз гаскәрләре җәбереннән һәм талавыннан, түләнмәгән әҗәтләрдән һәм эшләп түләүләрдән котылуга омтылыш яшәгән. Мондый кешеләр бөтен общиналары белән татарлар ягына чыкканнар, бу аларга тыныч тормыш һәм куркынычсызлык тәэмин иткән, салымнарны да азрак түләгәннәр. Аларда халык хакимияте оешкан, аксакаллар идарә иткән. Аларны «татар кешеләре» дип атаганнар. «Салымнар түләү һәм хуҗалык итү ягыннан аларга үз кенәзләре һәм боярлары астында яшәүгә караганда татарлар белән яшәве җиңелрәк булгандыр, мөгаен»,— дип яза Михайло Грушевский. Ә татарларның урыс җирләренә һөҗүмнәре күбесенчә кенәзләр-

нең үзара сугышларын туктату өчен ясалган. Һәрхәлдә, инде күп «чәйнәлгән» «изү» вакытында Русьның халкы ике тапкырга арткан. Чагыштыру өчен: Явыз Иван Казанны алгач киресенчә килеп чыккан — халыкның өчтән бер өлеше юкка чыгарылган, бу исә демографик катастрофа дигән сүз.

Тарихта яулап алуга шатлану очрагы юк. Мәсәлән, Явыз Иванның Казанны алган көнен — 1552 елның 2 октябрен бәйрәм итсәләр, бик гаҗәп булыр иде. Киресенчә, бу — кайгы көне. Урыс җире өчен дә шулай. Шулай да объективлык йөзеннән тулаем вазгыять турында сөйләргә кирәк, ул татар белән урыслар арасындагы каршылыктан гына түгел, башка көчләрнең дә нисбәтеннән гыйбарәт.

XIII гасырда Русь ике ут арасында: татар-монголлар килгән Көнчыгыш һәм тәре йөртүчеләр килгән Көнбатыш арасында калган. Теләсә кайсы очракта чит ил «изүе» көткән. Татар һәм Көнбатыш «изүе» арасыннан берсен сайлап алырга кирәк булган. «Татар дәрәҗәсе явызлардан-явыз: Урыс җиренә, Киевка, Володимирга, Галичка ия булган элеккеге бөек кенәз Данила Романович... хәзер тезләнде һәм холоп дип атала... Татар дәрәҗәсе явыз — аның әтисе Урыс җирендә патша иде, Кыпчак җирен буйсындырган һәм башка барлык илләргә яу чапкан иде» дип яза урыс елъязмасы.

Даниил Галицкий Көнбатышны сайлап алган һәм аның ярдәме белән Көнчыгышка каршы көрәш алып барырга, мөстәкыйль Галич-Волынь кенәзлеге төзергә һәм король таҗын алырга маташкан. Ул Папа Иннокентий IV белән чиркәү униясе турында сөйләшүләр алып барган, һәм аны урыс руханиларына ташламалар ясалыр дип ышандырганнар. Даниил король титулы алса да, Пападан ярдәм булмаган, әмма татарларга каршы тәре походы игълан ителгән.

Ләкин Папа схизматикларга — грекларга һәм урысларга каршы шулай ук тәре походы игълан иткән, ә Русьның католик Европага каршы торырлык көче булмаган. 1237 елда Тевтон һәм Кылыч йөртүчеләр орденнарының рыцарь-монахлары Балтыйк буен яулап алу һәм Руська керү, католиклыкны көчләп тагу максатында бик куәтле Ливон орденына берләшкәннәр. Бу чын-чынлап куркыныч нәрсә Новгород җирләре чигендә үк барлыкка килгән, өстәвенә кайбер җирләрдә урыслар арасында Тевтон яклы партияләр булган.

Александр Невский башкача хәл иткән. 1248 елда Папа булласында Александр Невскийга Рим тәхетен таныган очракта, татарларга каршы Ливон рыцарьлары ярдәме вәгъдә ителгән. Икенче яктан, Батый Александрга хәбәр җибәргән: «Урыс хакимнәре арасында данлы Александр, сезгә мәгълүм, Ходай миңа күп мәҗүси (халыкларны) буйсындырды һәм барысы да минем державага буйсыналар. Шулар арасыннан берүзең минем көчкә буйсынмаска уйлыйсыңмы? Исеңдә калдыр: үз җиреңне бөтен килеш сакларга уйласаң, һич кичектермичә миңа кил һәм минем патшалыгымның данын һәм абруен күрерсең, үзеңә һәм җиреңә файда табарсың». Александр Невский Көнчыгышны сайлаган.

Латинчылык сугышчан дин булган, ул православиене мөртәтлек дип санаган, ә «Яса» барлык диннәрне дә тигез күргән һәм дини кануннар түгел, сәяси-гражданлык законнары керткән. «Татарлар, иң актык чиктә — тән колы, әмма җан колы булмаганнар,— дип яза Г.В.Вернадский,— латинчылыкта исә җанның үзен бозу куркынычы янаган». Александр Урдага бертуганы Андрей белән барган һәм Батый ханның улы Сартак белән дуслашкан. Аннан алар Каракорымга Гуйук хан янына киткәннәр. Бу эшкә ике ел вакыт киткән. Һәм Андрейга — Владимирны, Александрга Новгородны һәм Киевны биргәннәр. Тверьда өченче бертуганнары — Ярослав кенәзлек иткән.

Андрей шведлар, ливонлылар һәм поляклар белән берлек яклы булган, ул татарлардан котылырга теләгән. Александр, өлкән абый буларак, энеләреннән буйсынуны таләп иткән. Буйсынмаганнарын күргәч, ул татарлардан файдаланган. 1252 елда нойон Неврүйнең татар отряды Андрейны Владимирдан куып чыгарган һәм бөек кенәз тәхете Александрга бирелгән. 1256 елда ул Ярославны да куып җибәргән, аннан соң ясак түләргә теләмәгән Новгород кешеләренә җәза биргән.

Урыс православиесе традицияләре буенча Александр Невский изгеләр арасына кертелгән. «Татарлар белән Русь арасындагы фаҗигале халәте Изге Александрны газап чигүче итә,— дип яза Н.А.Клепинин.— Ул Урыс чиркәвенә дә, урыс тарихына да, халык аңына да әнә шул газап чигүче таҗын киеп керә». Газаплы уйлар кемне күбрәк җәфалагандыр: Александр Невскийнымы, Даниил Галицкийнымы — әйтүе кыен, әмма бу вазгыятьнең фаҗигасе ике явызлыктан берсен сайлау мәҗбүрилегеннән гыйбарәт.

Даниил Галицкий — немецлар, ә Александр татарлар яклы булган. Ә кем урыслар яклы булган соң? Бер якны да кабул итмәүчеләр дә очраган. Полоцк, Туров-Пин кенәзлекләре татарларга да, немецларга да буйсынмаганнар, ләкин тарихта да эз калдырмаганнар. Татарлар кагылмаган Новгород җире тышкы дошманга, ягъни рыцарьларга каршы торырга тулысынча сәләтсез икәнлеген күрсәткән. Новгородка, янәсе, «татарлар тарафыннан суелган» Владимир кенәзлеге ярдәм иткән. Ә татарлар кагылмаган җирләр, ягъни Полоцк, Смоленск, Туров-Пин кенәзлекләре ни Новгородка, ни Псковка тевтонлылар һөҗүмен кире кайтарырга берничек тә булышмаганнар. Новгород белән «орден немецлары» арасында солых 1269 елда Урда отрядлары җибәрелү аркасында ирешелә: «Новгород җирендәге немецлар, татарларның исеменнән үк бик нык куркып, тынып калдылар». Тевтонлыларны куып җибәрү өчен бары тик 500 татар җайдагы җиткән.

Псков һәм Новгород нәкъ менә шул рәвешчә коткарылганнар. Көнбатыш урыс шәһәрләреннән иң озак каршы торганы — Смоленск, әмма ул да 1274 елда Алтын Урдага үзе теләп кушылуны Тевтон оккупациясеннән өстенрәк күргән. Ә бит татарлар Смоленскига хәтта якын да бармаганнар.

Урыс кенәзлекләрендә бернинди әхлакый башлангыч та, Урыс җирен берләштерүче кыйммәтләр дә булмаган, хәтта православие дә ул заманда вак акча сыйфатында булган, аны, җае чыкса, җиңел генә католиклыкка алмаштыра алганнар. Ә православиене саклап калырга әзер булганнар исә татарлар ягына чыкканнар, Александр Невский изгеләр рәтенә нәкъ менә шуның өчен кертелгән дә инде.

Үз чиратында татар-монголларның да ике көчле дошманы булган: Багдад хәлифе һәм Папа. Батый хан урыс кенәзләре белән дуслашырга теләгән,чөнки Папа татарларга каршы да, православиегә каршы да тәре походы игълан иткән. Европага походы вакытында Батый хан туганнан туган абыйларыннан ярдәм күргән, әмма ул ярдәмнең дә чиге булган. Тарихчылар бәяләвенчә, Көнбатышка походта гаскәрләрнең саны 30 — 40 мең җайдактан артмаган. Ә инде 1238 елда Үгәдәй улы Гуйук һәм Чыгытай улы Бори белән ачуланышканнан соң, шаһзадәләр дружиналары белән бергә Монголиягә чакырылып алыналар. Чыңгыз хан бүлеп биргән 4 000 монгол гаиләсенә баш булып, Батый бик зур илнең хакименә әйләнгән. Рәшидетдин раславынча: «Телгә алынган шушы дүрт әмирне Чыңгыз хан дүрт меңлек гаскәр белән Җүчи ханга бирде. Хәзерге вакытта Туктай һәм Баян гаскәрләренең зур өлеше — шушы дүрт меңнең нәселе, ә соңгы вакытта өстәлгәннәр — урыс, чиркәс, кыпчак, мажар һәм башкалар гаскәрләреннән килеп кушылганнар». Үгәдәй үлгәннән соң, бөек хан булып Гуйук калган, ә Батый, аның белән ачуланышу сәбәпле, аның ярдәменә исәп тота алмаган. Ул, Көнбатыш походын туктатып, көннән-көн мөстәкыйльләшә барган Алтын Урданы ныгыта башлаган. Венгр походыннан кайтышлый, 1242 елда ул Бөек Болгарда тукталган, урыс кенәзләре аның янына кенәзлек итү ярлыклары сорап килгәннәр һәм «һәрберсе үз җиренә» кайтарган. Ә бөек кенәз Ярослав «Урыс телендәге барлык кенәзләрнең өлкәне бул» дигән сүзләр белән кайтарып җибәрелгән. Бу датаны Алтын Урданың мөстәкыйль дәүләт сыйфатында Монгол империясеннән аерыла башлаган елы дип санарга мөмкин. Шуннан башлап Батый бары тик үз көченә генә таянган. Ул Александр Невский белән дуслык Урданы көнбатыш яктан ышанычлы саклый дип дөрес санаган. Шундый көчләргә ия һәм ярдәмгә мохтаҗ Батый хан, нигездә, деспотлык режимы, башкача әйткәндә «изү» урнаштыра алмаган. Шуңа күрә Алтын Урда үзенә бертөрле конфедерация булган: ул бер яктан — төрле халыкларның һәм конфессияләрнең үзара мәнфәгатьләренә, икенче яктан — хәрби осталык ягыннан көндәшләре булмаган татарлар һөҗүменнән куркуга таянган.

Мондый «берлек»тән урыслар да, татарлар да откannар, католиклык оттырган. Моннан ары православие ышанычлы сакланган. Монголларга кадәр дәвердә славян дөньясының кырыйлары мәҗүси булып кала биргән. «Бары тик «татар-монгол изүе» вакытында гына,— дип яза Ю.Кобищанов,— иркенләп монастырьлар төзү, авыл кешеләрен чукындыру, «аю почмакларын» (Бөек Ростовның мәҗүси җире шулай аталган) Изге Руська әйләндерү башланган». Александр Невскийның өметләре акланган. Нәкъ менә «изү» православие культурасының чәчәк атуына ярдәм иткән. Салымнардан азат ителгән православие монастырьлары урыс халкының куәтле рухи көченә әверелгәннәр. Урысларның XIV гасырдагы икона язмалары Русиянең генә түгел, дөньяның рәсем сәнгате тарихында иң югары нокта булып санала һәм бу очраклы түгел. Татарлар керткән өстен хокуклар исә Явыз Иван вакытында 1584 елгы Земский соборда юкка чыгарылганнар: «Анда барлык тарханнарны яки хөкемнән һәм салым түләүдән монастырь вотчиналары файдалана торган ташламаларны бетерү, монастырь җирләреннән дә, башка җирләрдән түләнгән кебек салым түләү билгеләнде».

Татарлар Александр Невский ярдәменнән башка Алтын Урдада тыныч кына хакимлек итә алмаслар иде, әмма урыслар Алтын Урдадан башка православиене югалтырлар иде, димәк, Русия җире бүген без аңлаганча Русия булмас иде, башкача әйткәндә, без Речь Посполитая яки Бөек Литва дәүләтендә яшәр идек. Яхшымы бу, начармы — башка мәсьәлә, ләкин бу факт.

Александр Невский һәм Даниил Галицкий урыс тарихындагы борынгы ике культура тибын чагылдыралар: «көнчыгышчы» тип һәм «көнбатышчы» тип, әлеге нигездә соңрак урыс фикеренең ике агымы барлыкка килгән, алар «славянофиллар» һәм «көнбатышчылар» дип аталганнар, алар дәүләтнең нигезләренә үк кагылганнар һәм хәзергә кадәр иҗтимагый фикергә тәэсир итеп торалар.

## «Каян килеп чыккан Урыс җире һәм нинди Урыс җире барлыкка килгән?»

*Идел-йортны дау алды,*
*Яу өстенә яу килде,*
*Идегәй әйткән көн килде.*

*Чыңгызның куйган хан тагы*
*Кан тагы булып әверелде;*
*Хан сарае камалды.*
*Кырым, Казан, Аҗдаркан*
*Башлы-башлы ил булды,*
*Алтын Урда таралды.*

«Идегәй»

Русияне Русьтан нәрсә аерып тора? Территория буенча түгел, рухи яктан, ягъни әверелешнең асылы нидән гыйбарәт? Бу сорауга җавап үткән заманда гына түгел, хәзерге вазгыятьтә дә күп нәрсәне аңлатып бирә ала. Русь та, Русия дә — этник планда катлаулы төзелмә. Русьта күпсанлы славян ырулары гына түгел, бик күп төрки халыклар да яшәгән, Новгород кырыйларында фин-угырлар да аз булмаган, ә Мәскәү яки Түбән Новгород турында әйтәсе дә юк, алар бөтенләй мордва җирләрендә корылганнар. Өстәвенә төрле халыкларның бергә яшәве сәяси төсмергә дә ия булган. Мәсәлән, кыпчак гүзәлләре («половецкие красны девицы») күп кенә урыс кенәзләрен, шул исәптән Александр Невскийны да тудырганнар. Кыпчаклар Чернигов, Галицкий һәм Суздаль кенәзләренең Киев кенәзләренә каршы берлектәшләре булганнар, чөнки Киев кенәзләре кыпчакларга дошман булган төркиләргә таянганнар.

Урыс җирләрен җыючы Мәскәү кенәзлеге баштан ук үз составына татарларны гына түгел, литваларны да, шулай ук фин-угырларны да туплаган. Бүгенге көндә татарлар Мәскәүдә яшәгән һәм эшләгән шикелле, Урдада да күп кенә татарлар Мәскәүгә күченгәннәр: яхшырак эш эзләгәннәр яки исламга күчәргә теләмәгәннәр, вакытлар узгач, православиене кабул иткәннәр. Борис Годуновның борынгы бабасы Морза Чет XIV гасырда Костромада Ипатьев монастыре төзегән, соңыннан ул монастырь Романовларга калган. Ул заманнардагы документларда әле татар исемнәре яңгырый. 1584 елда Рязань җирендә күршеләре дьяк А.Шәрәфетдиновтан зарланалар, «патшабыз, ул синең поместье җирләрен үз вотчинасы җирләренә кушып сукалый, синең авылларыңдагы крестьяннарыңны әйтмичә генә үзенә эшләтеп йөртә...» Татар исемнәре православие исемнәренә бик күпкә соңрак алмаштырылган.

Мәскәүнең күтәрелүе Иван Калитадан башланган, ул да үз сәясәтенең нигезе итеп татарлар белән берлекне сайлаган. «Ханга баш ияргә кенәзләр арасыннан Калитадан ешрак берәү дә йөрмәгән,— дип яза В.О.Ключевский,— ул анда һәрвакыт көтелгән кунак булган, чөнки ул буш кул белән бармаган. Урдада инде болай уйларга күнеккәннәр: Мәскәү кенәзе килсә, Алтын Урданың бөек хан-патшасының, ханбикәләренең һәм барлык атаклы морзаларының «күп алтын һәм көмеш»е булачак. Шуның аркасында генеалогия ягыннан үз туганнары арасында иң кечесе булса да, Мәскәү кенәзе өлкән бөек кенәзлек тәхетенә ирешкән. Хан Калитага баш күтәргәне өчен Тверь кенәзенә җәза бирергә кушкан. Калита бу йомышны төгәл үтәгән: аның җитәкчелегендә татарлар Тверь кенәзлеген туздырганнар. Һәм бөтен Урыс җирен бөлдерделәр» — дип өсти елъязмачы.— Әлбәттә, Мәскәүгә кагылмаганнар. Бу эше өчен Калита бүләкләнгән: аңа 1328 елда бөек кенәзлек тәхете бирелгән, шул вакыттан бирле бу тәхет Мәскәү кенәзе кулында калган». Башта Үзбәк ханның, аннан соң аның улы — елъязмачылар атаганча «игелекле патша Җанибәк»нең ярдәме аркасында Калита бөтен Русь өчен ясак түләү вазифасын үз өстенә алган. Мәскәү ясакны салым сыйфатында бөтен урыс кенәзлекләреннән җыеп алып аны Урдага түләгән. Аннары Иван Калита бөлгенлеккә төшкән удел кенәзләренең җирләрен сатып ала башлаган. Ул сатып алган нәрсәләр арасында хәтта борынгы Ростов шәһәре дә булган. Калита кешеләрне үзенә хезмәткә эшлекле сыйфатларына карап алган. Алтын Урда татарлары урысның атлы гаскәренең нигезен тәшкил иткәннәр, бу гаскәр нәтиҗәдә күп җиңүләргә шул исәптән Куликово кырындагы сугышта җиңүгә китергән. Мәскәүдә православие идеологик өстенлеккә ачыктан-ачык ия булган.

Елъязмачы бәян итә: аталары үлгәч, Калитаның балалары Үзбәк хан янына барганнар, хан аларны ихтирам белән, якын итеп, яратып каршы алган, чөнки аларның аталарын яраткан һәм хөрмәт иткән. Хан аларга бөек кенәзлекне алардан башка берәүгә дә бирмәскә вәгъдә иткән. Бөек кенәз итеп Калитаның олы улы Семен куелган, аның «кулы астына» бөтен урыс кенәзләре бирелгән. Семен Гордый ханның өметләрен аклаган. Бөек кенәзлек Иван Калита династиясе кенәзләренең нәсел хокукына әйләнгән. Моның белән Киев Русенең сәяси традициясе ахырынача бетерелгән. Мәскәү Русе Киев башлангычын өзгән һәм дәүләт төзүнең башка принципларын тудырган. Киев Русе мирасының әһәмиятен инкарь итәргә ярамый — православие аннан башланган, әмма, дәүләт төзелеше күзлегеннән караганда, Киев бернинди үрнәк күрсәтмәгән, ул вакытта Киев Литва составына кергән.

Мәскәүнең күтәрелүе күпләргә ошамаган. Суздаль кенәзләре удел тәртипләре ягында торганнар. Алар татарлар ясагыннан канагать булганнар, аны Идел буендагы бай шәһәрләр, шул исәптән Түбән Новгород та һич авырыксынмыйча түләп барган. Аларның көче илне берләштерүгә түгел, сәүдәне үстерүгә юнәлдерел-

гән. Алар татарлар белән дус булганнар, әмма мәскәүлеләрдән аермалы буларак, татарлар белән кан катыштырмаганнар, бары тик янәшә генә яшәгәннәр.

Куликово сугышы алдыннан Алтын Урдада да, урыс кенәзлекләрендә дә шактый катлаулы мөнәсәбәтләр туган. Туктамыш традицион сәясәт — Русь белән берлек ягында булган, ә Мамай исә Көнбатыш белән берлеккә, башлыча Кырымдагы Генуя колонияләренә таянган. Мамай мәскәүлеләрне Генуя кешеләренә Русьта сәүдә итәргә һәм ясак җыярга рөхсәт итәргә үгетләп маташкан. Генуя кешеләре инде бер тапкыр Мамайдан Русьта ясак җыю хокукын сатып алган булганнар, бу исә керемнәренең бер өлешен югалткан кенәзләр арасында гына түгел, гади халык арасында да нәфрәт тудырган. Тәкъдиме кире кагылгач, Мамай литвалар белән берлектә Русьны ике өлешкә бүләргә карар иткән. Хәер, ул вакытка Алтын Урда Идел буйлап ике өлешкә: уң һәм сул канатларга аерылган булган инде. Мамай чынлыкта көнбатыш өлешенә хакимлек иткән.

Урыс кенәзләре арасында Литва һәм Мамай белән берлек яклылары да булган. Мәскәү яклы көчләр тарафыннан төшерелгән Тверь кенәзе Михаил Александрович 1367 елда ярдәм сорап Литвага качкан, аннан ярдәм алып үз җирләрен кире кайтарган. Нәтиҗәдә Мәскәү белән Тверь арасындагы мөнәсәбәтләр тагын да кискенләшкән. Михаил Ольгердтан ярдәм сораган. «Ольгерд Литва гаскәре башында, Смоленск һәм Тверь көчләре белән ныгытылып, шул ук елның көзендә Мәскәүгә каршы походка чыккан, аны көньяк-көнбатыштан уратып узган. Дмитрийның барлык көчләре дә Мәскәүгә җыелырга өлгермәгән. Ольгерд марш белән ыргылып, үз юлында Мәскәүнең тоткарлагыч отрядларын кырып, 1368 елның октябрендә Мәскәүгә барып җиткән һәм аның таш Кремлен камап алган. Анда Дмитрий, Владимир Серпуховский һәм митрополит Алексий качып утырганнар. Ольгерд шәһәрне өч тәүлек камап торган, Кремльне ала алмаган һәм «кире кайтып киткән», «христианнарга күп явызлык кылган». Замандашлар болай дип язганнар: «Моңарчы Руська Мәскәүгә Литва тарафыннан кылынган кадәр явызлык кылынганы юк иде, хәтта татарлар тарафыннан да». Моңа җавап итеп Дмитрий 1370 елның 1 сентябрендә Тверь кенәзлегенә гаскәре белән шәхсән үзе килгән, «бөтен Тверь волостенда сугыштылар, авылларны яндырдылар, кешеләрне әсирлеккә алып киттеләр, ә кайберләрен үтерделәр». Җавап итеп Михаил Александрович Урдага Мамай янына барган, чөнки «үзе бөек кенәзлекне алырга теләгән һәм Урда кенәзләренә һәм кешеләренә күп бүләкләр биреп, күп нәрсәләр вәгъдә итеп, үзен бөек кенәзлеккә чыгаруларын сораган». Михаил бөек кенәзлеккә ярлык турында үтенечендә нык торган, әмма Дмитрий да вакытны бушка уздырмаган һәм үз чиратында Урдага ярлык сорап барган һәм аны алып та кайткан. Мәскәү бер үк вакытта Литва белән дә уртак тел табарга тырышкан. Владимир Серпуховский Литва княжнасына өйләнгән, һәм бу никах бик уңышлы булып чыккан. Урданың эчке низаглар аркасында көчсезләнгән үзәк хакимияте Мәскәүгә һәм Тверьга үзләренең эчке генә түгел, тышкы сәясәтләрен дә үткәрергә ирек биргән.

Урда тәхете өчен көрәш тынмаган. 1374 елның көзендә Орыс, башкаланы яулап алып, үзен бөтен Урда ханы дип игълан иткән. Иң беренче булып аңа баш ияргә Түбән Новгород кенәзе килгән, соңыннан ул бүтәннәрне дә Орыс белән берлеккә тарткан. Мәскәү кенәзе Дмитрий Мамай белән Орыс каршылыгында Орыс ягына баскан, ә Тверь кенәзе Мәскәүгә яу чапкан, ләкин Литвадан һәм Мамайдан ярдәм күрмәгән һәм җиңелгән, Дмитрий куйган шартларга риза булып үзен «кече туган» дип таныган: «Ә безгә яки сиңа татарлар (ягъни Мамай) һөҗүм итсә, безгә дә, сиңа да, барыбызга да аларга каршы бергә сугышырга кирәк булачак». Бу вакытта Мамай үзе өчен иң мөһим мәсьәләне хәл итүгә — Урда башкаласын яулауга керешкән һәм 1375 елда аны алган да. Михаил Тверской, Мәскәү белән килешүгә карамастан, Литва белән аралашуын дәвам иткән, атап әйткәндә, үзенең улы Иванны Кейстут кызы Мариягә өйләндергән. Кенәз Олег Рязанский да Литва кенәзе Ягайло сеңлесенә өйләнгән һәм Литва яраны булып Мамай ягында торган.

Мамай инде икенче елны ук башкаладан коры калган һәм үзенең Днепрдагы ставкасына киткән. Дмитрий алдында тагын «Кайсы якны сайларга?» дигән сорау туган, һәм ул Алтын Урданың яңа ханы Каганбәк ягына баскан, Каганбәк Мамай белән көрәштә актив ярдәм таләп иткән. Атап әйткәндә, Каганбәк Болгарның тулысынча буйсынуын теләгән. Бу эшне ул Түбән Новгород һәм Мәскәү кенәзләренә йөкләгән, болары аны 1377 елның 16 мартында уңышлы башкаралар, урыс воеводалары Болгарга акча контрибуциясе салалар, хан даругачысын һәм тамгачысын утырталар да өйләренә кайтып китәләр, авылларны һәм йортларны яндыралар, ә кешеләрне үтерәләр.

Бу вакытта Алтын Урданың сул канатында Туктамыш хан алга чыккан. Аның алдына Мамай белән көрәш бурычы килеп баскан. Мамайны җиңмичә торып, Алтын Урданы берләштерү мөмкин булмаган. Әлеге вазгыятьтә урыс кенәзләре өчен иң мөһиме — оттырмау, көчлерәк якка вакытында чыгып калу, ә Мамайга исә үзенең тылын ныгыту, башкача әйткәндә, урыс кенәзлекләрен буйсындыру зарур булган. Куликово сугышы алдыннан вазгыять менә шундый. Алтын Урданың ике канаты, Литва һәм төрле юнәлештәге урыс кенәзлекләре катлаулы сәяси мозаика тәшкил иткәннәр.

Дмитрий Донскойның 20 меңлек атлы гаскәре татарларның ат тезмәләрендә өйрәтелгән керәшен татарларыннан, литвалардан һәм урыслардан торган. Калган 130 меңен кенәзләрнең атлы һәм җәяүле дружиналары, шулай ук ополчение тәшкил иткән. Тверь бу сугышка катнашудан баш тарткан. Дмитрийга ярдәмгә Себер татарлары белән Туктамыш хан чыккан. Дмитрий белән Туктамыш арасында алдан килешенгәнлекнең турыдан-туры дәлилләре юк, әмма объектив рәвештә максатлары уртак булган. Мамайны җиңгәннән соң шунда ук үзара илчелек алмашулары шушы хакта сөйли. Барысыннан да алдарак Урдага үзенең илчелеген Бөек Мәскәү кенәзе җибәрә — «октябрьнең 29 нчы көнендә», ягъни сугыштан соң бары тик ай ярым гына вакыт узгач. Туктамыш үз чиратында Мамайны Калка елгасында тар-мар итеп, «илчеләрен кенәз Дмитрийга һәм барлык урыс кенәзләренә җибәреп, үзенең килүе, тәхеткә утыруы турында һәм аларның дошманы Мамайны җиңүе турында, Идел патшалыгына утыруы турында хәбәр бирде. Урыс кенәзләре исә аның илчеләрен Урдага ихтирам күрсәтеп һәм күп бүләкләр белән кайтарып җибәрделәр, ә кышын һәм язын шул илчеләр артыннан һәрберсе үз кешесен зур бүләкләр белән җибәрде» дип дәлилли «Пространная летописная повесть о Куликовской битве, о побоище, которое было на Дону, и о том, как князь великий бился с Ордою». Шуңа күрә Дмитрий белән Туктамышның Мамайга каршы бергәләп көрәшү турында турыдан-туры килешенгәнлеген сызып ташларга ярамый.

Мамайның 200 меңгә якын сугышчысы булган. «Пространная летописная повесть о Куликовской битве.» әсәрендә болай дип раслана: «Шул ук көздә Урда кенәзе Мамай үз фикердәшләре һәм Урданың башка барлык кенәзләре, барлык татарлар һәм половецлар көче белән килде, моннан тыш тагын гаскәр яллады: һәм басурманнар, һәм әрмәннәр, һәм фряглар, һәм чиркәсләр, һәм яслар, һәм бортаслар. Ә Мамай белән бергә, аның белән берлектә, Литва кенәзе Ягайло да үзенең барлык Литва һәм Лях көче белән, алар белән бергә Рязань кенәзе Олег Иванович та — менә шушы җинаятьтәшләре белән бөек кенәз Дмитрий Ивановичка һәм аның туганы Владимир Андреевичка каршы чыкты». Мамайга ярдәмгә баручы Литва кенәзе Ягайлоның гаскәрендә күпчелек Минск, Полоцк һәм Гродно тирәсеннән урыслар булган. Рязань кенәзе турында «Сказание о мамаевом побоище» әсәрендә болай диелгән: «Аның башында акылы чамалы иде, ул денсез Мамай янына зур ихтирам һәм күп бүләкләр белән үзенең улын җибәргән һәм аңа үз грамоталарын болай дип язган: «Көнчыгыш ханы, бөек һәм ирекле патшаларның патшасы Мамайга — шатланырга! Син куйган кенәз, сиңа ант иткән Олег, Рязань кенәзе, синнән үтенә. Ишеттем мин, әфәнде, Урыс җиренә, үзеңнең хезмәтчең кенәз Дмитрий Ивановичка каршы яу белән барырга телисең икән, без аңа, ачуланып, синең олуг исемең белән ничек кенә янасак та, ул бу турыда кайгырмады. Һәм тагын, безнең патша әфәндебез, ул минем шәһәрем Коломнаны тартып алды — боларның барысы турында да, о, патшабыз, сиңа зарларыбызны җиткерәбез». Олег Рязанский үзенең тагын бер илчесен, шатлана-шатлана, Ольгерд Литовскийга җибәргән: «Безнең заман килде, чөнки бөек патша Мамай аңа һәм аның җиренә киләчәк. Һәм хәзер, кенәз, без икебез дә Мамай патшага кушылыйк, чөнки мин беләм, патша сиңа Мәскәү шәһәрен һәм синең кенәзлеккә якын булган башка шәһәрләрне дә бирәчәк, ә миңа ул Коломнаны, минем кенәзлеккә якынрак урнашкан Владимирны да, Муромны да бирәчәк».

Бүген Куликово сугышын рәсми төстә урыс коралының татарларны җиңүе дип бәйрәм итәләр һәм ул Русия дәүләтенең хәрби җиңүләре исемлегенә кертелгән. Бу хәл хәтта сәерлекнең дә теге ягында. Дмитрий Донской татарлардан, литвалардан һәм урыслардан торган гаскәр башында, гаскәре шул ук урыслардан, литвалардан һәм татарлардан, тагын әле әрмәннәрдән, генуялылардан, чиркәсләрдән торган Мамайга каршы чыккан. Урыс-татар мөнәсәбәтләренең һәм урыс коралы гайрәтенең биредә ни катнашы бар соң? Валерий Захаров болай дип яза: «Сорарлар: Куликово кырында Русь кем белән сугышкан соң? Ну, әлбәттә, Урда белән түгел. Чөнки Урданың иң яхшы атлы укчылары — ул заманның иң профессиональ сугышчылары — Дмитрий Донской ягында сугышканнар һәм чынлыкта урысларга Мамайны җиңүне тәэмин иткәннәр. Көлкеме? Әйе, бөек урыс тарихын һәрдаим бозып, безне ни дәрәҗәдә юләрсетергә мөмкин булганлыгына төшенсәң, чыннан да көлке. Чын тарих европоцентризм әзерләп куйган «прокруст ятагына» сыймый ул...». Сүз уңаеннан, Куликово сугышы булган урын хәзергәчә табылмаган, ә бүген Куликово кыры дип аталган җирнең әлеге атаклы сугышка бернинди дә катнашы юк — анда археологлар сугыш эзләре тапмаганнар. Ул җирдә берәү дә сугышмаган.

Бәс, шулай булгач, халык хәтерендә һәм елъязмаларда нык сакланып калган ул сугышның мәгънәсе нидә соң? Урыслар Мамай белән сугышканнар, чөнки ул «йөрәгенә усаллык салып, законлы ханга каршы чыккан», ягъни аның, Чыңгыз нәселеннән булмау сәбәпле, халык алдында тәхеткә хокукы булмаган, ул гына да түгел, Мамай ясак җыю хокукын Генуя кешеләренә — католикларга биреп ясак җыюның инде гадәткә кергән тәртибенә каршы чыккан. Урыслар чыңгызчылар урнаштырган тәртипләр яклы булганнар. Мондый мөнәсәбәт Алтын Урданың бөтен чорына хас. Урыслар Алтын Урданың законлы ханнарын, ягъни чыңгызчыларны бервакытта да үзләренең гомерлек дошманнары дип санамаганнар. Урдадан аерылып чыгу данын Иван III кә сылтыйлар, бу исә дөреслеккә туры килми. Ул, дәүләттә законлы тәртипне яклап, Зур

Урда ханы Әхмәткә, ягъни үзен-үзе хан дип билгеләгән кешегә каршы чыккан. Ул Алтын Урда белән сугышмаган да, аның нигезен дә какшатмаган. Ул нигез урыслар ярдәменнән башка — үзеннән-үзе какшаган. В.О.Ключевский болай дип язган: «Иван тышкы мөнәсәбәтләрдә дә тантаналырак адымнар ясый башлаган, Урда изүе сугышсыз-нисез, татарларның үз ярдәме белән җилкәдән төшкәч, бу аеруча ачык күренгән».

Урда да үз итмәсәләр дә, аның белән исәпләшкәннәр, еш кына ярдәм өчен дә аңа мөрәҗәгать иткәннәр. «Повесть о Петре, царевиче ордынском» әсәрендә хан җир йөзендәге иң югары гаделлек дип кабул ителгән. Үпкә-низаг корылганда, «Урдага дөреслек эзләп» барганнар, бөек хан илчелек әзерләгән һәм мәсьәләләрне гадел хәл иткән.

> *«Хан илчесе Ростовка килгән, Петр һәм Павел монастыре күле янында туктаган да кенәзләрне Петр Ордынскийның оныклары белән хөкемгә чакырган. Кенәзләр хан илчесеннән куркып төшкәннәр. Ә Юрий илче алдына Петрның барлык грамоталарын салган. Илче аларны карап чыккан да кенәзләрдән сораган:*
>
> *— Бу грамоталар ялган түгелме? Ростов күлендәге су чыннан да сезнекеме? Сезнең суыгыз астында сезнең бабагыз саткан җир бармы? Сез ул җир өстеннән үзегезнең суыгызны алып куя аласызмы?*
>
> *Һәм кенәзләр җавап биргәннәр:*
>
> *— Ей-ей, бу грамоталар ялган түгел, әфәнде! Биредә су да безнеке, аның астында җир дә бар. Тик без суны аның өстеннән алып куя алмыйбыз шул, әфәнде!*
>
> *Шулчак хан илчесе мондый хөкем чыгарган:*
>
> *— Алып куя алмыйсыз икән, нишләп аны безнең су дип атыйсыз соң? Ул Алла тарафыннан барлык кешеләр өчен яратылган күл! Әгәр җире сатып алынган икән, димәк, аның өстендәге суы да сатып алынган!*
>
> *Шул рәвешчә ул күлнең суын җир биләмәләре чикләре буенча Петр оныгы Юрийга биргән. Һәм Юрийга хан кушуы буенча алтын мөһерле грамота тоттырып кайтып та киткән. Шулай итеп, Ростов кенәзләре Юрийга бернинди дә явызлык кыла алмаганнар. Алар озак вакытларга тынып калганнар».*
>
> «Повесть о Петре, царевиче ордынском». XIII гасыр

Куликово сугышы вакытында яшәгән кешеләр фикере буенча, Туктамыш — законлы хан, ә Мамай аңа буйсынырга тиеш булган. «Повесть о нашествии Тохтамыша» әсәрендә Туктамыш — патша, ягъни законлы, легитим хаким дип аталган. А.В.Быков һәм О.В.Кузьмина болай дип язалар: «Урыс кенәзләре үз алларына Алтын Урда составыннан чыгу максатын бөтенләй дә куймаганнар. Сугыш конкрет Мамай белән барган. Әмма акча аркасында гына түгел, Дмитрий Иванович Мамайга «искечә» ясак түләргә әзер булган. Куликово сугышының мәгънәсен салым күләме турында бәхәскә кайтарып калдыру да дөрес булмас иде. Әгәр дә мәсьәлә чынлап та шулай торса, бу сугыш Мамай белән Мәскәү кенәзе арасында булыр иде. Чынлыкта исә сугышка Дмитрий Иванович белән бергә күпчелек урыс кенәзләре һәм алар шәһәрләренең ополчениеләре дә чыккан. Алар өчен Мамай белән көрәш Русьта законсыз һәм үзләре өчен файдасыз тәртипләр урнаштырырга маташучы законсыз патшага каршы көрәш булган». Урыс елъязмаларын тора-бара, сәяси вазгыять ихтыяҗына туры китереп, еш кына күчереп язуларын һәм үзгәртүләрен дә исәпкә алырга кирәк. Ниндидер вакыйгалар купайтып күрсәтелгән, идеологик күрсәтмәләргә бәйле сюжетлар барлыкка килгән.

Куликово сугышын рәсми шәрехләүнең алдан ук ялгыш булуы кайбер галимнәрне һәм публицистларны һич көтелмәгән нәтиҗәләргә, хәтта бу фактның үзен тулысынча инкарь итүгә китергән. Әйтергә кирәк ки, моңа кадәр дә бу вакыйга төрлечә бәяләнгән. Мәсәлән, В.О.Ключевскийны татарларга теләктәшлектә һич гаепләп булмый. Әмма ул әлеге вакыйганы әһәмиятсез дип санап, үзенең урыс тарихы күренешләрен җентекләп тасвирлый торган күптомлы лекцияләреннән бөтенләй төшереп калдырган. Шул ук вакытта Куликово сугышын галәми үлчәмнәргә кадәр кабарткан тарихчылар да бар.

Хәзерге заман рәсми дәреслекләренең Куликово сугышын бәян итүе бик каршылыклы, моны стереотипларның чыдамлыгы белән генә аңлатып була: «Татарлар Куликово кырыннан паникага бирелеп, куркып качканнар. Сугышта шәхси батырлыгы һәм хәрби җитәкче буларак хезмәте өчен Дмитрийга Донской исеме биргәннәр. Җиңелгәннән соң Мамай Кефе (Феодосия) шәһәренә качкан, аны шунда үтергәнннәр. Урда хакимиятен Туктамыш үз кулына алган... Куликов кырында Алтын Урда беренче зур җиңелүгә дучар булган». Әгәр дә татарлар җиңелгән, ә урыслар җиңгән икән, ни өчен хакимиятне чыңгызчы Туктамыш үз кулына алган соң, аның урыс түгеллеге көн кебек ачык лабаса? Бу нәрсәләр бер-берсенә һичничек ялганмый.

Дәреслеге Көнбатыш университетларында гаять популяр булган Георгий Вернадский мәсьәләгә объективрак карый: «Урысларның монголлар хакимиятенә һөҗүме аларның дошманнары өчен авыр, ләкин үтергеч булмаган. Мамай шунда ук Мәскәүгә каршы яңа походка әзерләнә башлаган. Әмма иң элек ул Туктамышның бик тиз алга баручы көчләре белән сугышырга тиеш булган. Мамайның гаскәре тар-мар ителгән, ул үзе Кырымга качкан, һәм аны шунда Генуя кешеләре үтергән. Шуннан соң Туктамыш бөтен Җүчи олысының бәхәссез хуҗасы булып калган». Мондый шәрехләүдә татар һәм урыс каршылыгы Куликово сугышының төп эчтәлеге буларак юкка чыга һәм сәяси вакыйгаларның манзарасы киңәя. Һәм әлеге кысаларда Туктамышның Мәскәүне алуын аңлату җиңелрәк. Бу вакыйга Русия дәреслекләрендә татарлар рәхимсезлегенең үрнәге сыйфатында бик ачык тасвирланып килә.

Туктамышның Мәскәүгә походының төрле фаразлары бар. Шуларның берсе: ике ел буена ясак түләмәгән өчен, Туктамыш килгән дә посадны яндырган. Мәскәүгә «экзекуция» ясау бары тик бер генә нәрсә — Туктамышның кенәзне салым түләргә мәҗбүр итүе турында гына сөйли, шуннан да артык түгел. Бу эштә аңа Түбән Новгород һәм Рязань кенәзләре булышкан, алар Туктамыш белән бергә Мәскәүгә яу чапканнар. Мәскәүлеләр үзләре каршы тормаганнар, «хан үзенең ялчысы Дмитрийны җәзаларга килгән» дип уйлаганнар, өстәвенә Дмитрий Донской бу вакытта шәһәрдән качкан, ә ясакны түләгәч, «патша 8000 көмеш кабул иткән», кенәзлек итәр өчен Сарайга ярлык сорап барган, һәм, табигый ки, Туктамышның аркадашы буларак аны алып та кайткан.

Башка бер фараз Дмитрий Донскойга каршы яшерен берләшү булган һәм Туктамыш аны коткарып калган дип раслый. Бу фараз А.В.Быков һәм О.В.Кузьминаның «Эпоха Куликовской битвы» дигән китабында бәян ителгән. Авторлар болай дип саный: замандашлар Куликово сугышын бөек фаҗига дип, ә Дмитрий Донской белән митрополит Алексийның урыс җирләрен Мәскәү дәүләте тирәсендә үзәкләштерергә тырышуларын кенәзлекләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең инде урнашкан системасын җимерүче җинаятьчел гамәл дип кабул иткәннәр. Чиркәү аеруча ризасызлык белдергән, ул әле һаман славяннарны Киев тирәсендә берләштерү идеяләре белән яшәгән. Митрополит Киприан Куликово сугышында җиңүчегә ләгънәт укыган. Генуялылар өчен Мәскәү базары югалган, һәм алар урыс кенәзлекләре биләмәләрендә үз йогынтыларын кайтарырга ашкынганнар.

А.В.Быков һәм О.В.Кузьмина фикеренчә, яшерен берләшүне Нижний Новгород кенәзе оештырган. Мәскәүдә гаскәр дә, гади халык та аның ягында торган. Яшерен берләшү Рязань кенәзенә дә, Литваның бөек кенәзенә дә файдалы булган. Дмитрий Донской гаскәрләрне Мәскәүдән походка алып чыккач, фетнә күтәрелгән һәм ул Костромага качарга мәҗбүр булган, өстәвенә шулкадәр тиз качкан ки, хатыны белән яңа туган улын да Мәскәүдә калдырган. «Һәм вече җыелды, бөтен чаңнар сугылды. Фетнәче халыклар, яман кешеләр, баш күтәрүчеләр вечега җыелды: шәһәрдән чыгасы килгәннәрне чыгармыйча гына калмадылар, хәтта таладылар, митрополитның үзеннән дә оялмадылар, иң яхшы боярлардан да курыкмадылар, өлкән яшьтәге картларның агарган чәчләреннән дә уңайсызланмадылар». «Повесть о нашествии Тохтамыша» әсәрендә вакыйгалар шулай тасвирланган. Фетнәчеләргә булышыр өчен «Литваның ниндидер кенәзе, Остей исемлесе, Ольгердның оныгы килде. Ул, халыкларны ныгытып, шәһәр фетнәсен бетереп, алар белән шәһәрдә камалышта утырды, бик күп халыклар белән, күпме шәһәр кешесе калган — шулар белән, волостьлардан, башка шәһәрләрдән һәм илләрдән күпме килгән — шулар белән». Туктамыш походының максаты Мәскәүне Дмитрий Донской кулы астында калдыру булган. Башта хан, фетнәчеләрне үзләре теләп бирелергә үгетләргә тырышып, шәһәр диварлары янында торган, әмма моннан ачыктан-ачык баш тартуларын күргәч, сугыш хәрәкәтләре башларга мәҗбүр булган, бу исә посадны яндыру һәм шәһәр кешеләрен кыйнау белән төгәлләнгән. Әлеге фараз буенча, «Алтын Урданың яңа патшасы — патшалыгы, шул исәптән Дмитрийның Непрядва янында башларын салган полклары бәрабәренә дә алынган патша, шул рәвешчә үзенең тугры һәм бик кадерле вассалының какшап киткән хакимиятенә ярдәм күрсәткән. Һәм шул ук вакытта Урданың Мәскәү өстеннән хакимлеген дә саклап калган. Ә бит Мәскәү кенәзлегендә Литва яклы бу түнтәрелеш барып чыккан очракта, хакимиятнең Туктамыш кулыннан китү ихтималы булган» дип нәтиҗә ясыйлар А.В.Быков һәм О.В.Кузьмина. Туктамышка Мәскәүдә «беркатлырак һәм акрын кыймылдаучан, үҗәт һәм тәвәккәл, барысы өчен дә — хәтта Мәскәү һәм үз гомере өчен дә — Туктамышның үзенә бурычлы Дмитрий Иванович кирәк булган». Бу фаразның да үз дөреслеге бар. Әмма беренче фаразның да, икенчесенең дә төп эчтәлеге бер үк: Дмитрий Донской белән Туктамыш Мамайга каршы көрәштә аркадашлар булганнар.

Куликово сугышын урыс коралының татарларны җиңүе дип рәсми бәяләү тарихи елъязмаларга туры килми. Ни Дмитрий Донской, ни башка бөек кенәзләр Русьны Алтын Урдадан аерып чыгару максатын куймаганнар, алар сәяси көрәштә актив катнашканнар, өстәвенә Мәскәү кенәзләре, Тверь яки Рязань кенәзләреннән аермалы буларак, һәрвакыт законлы хакимият ягында торганнар. Куликово сугышы мәсьәләсендә Лев Гумилев бәяләмәсе белән килешергә мөмкин, ләкин билгеле бер төзәтмәләр ясап кына. Лев Гумилев

бу сугышка гомумрус үзаңы формалашу күзлегеннән караган. «1380 елда Куликово кырындагы вакыйганың этник әһәмияте гаять зур булган, — дип яза ул.— Суздаль, Владимир, Ростов, Псков кешеләре Куликово кырына үз кенәзлекләренең вәкилләре буларак барганнар, әмма аннан инде, төрле шәһәр кешеләре булсалар да, барысы да урыслар булып кайтканнар. Шуңа күрә дә безнең илнең этник тарихында Куликово сугышы әһәмиятле вакыйга булып санала: аннан соң яңа этник бергәлек — Мәскәү Русе — чынбарлыкка әйләнгән һәм тарихи әһәмияткә ия фактка әверелгән».

Удел-кенәз рухының державачыл рухка әверелеше, һичшиксез, бөек Русия идеясе барлыкка килү өчен хәлиткеч шарт булган, ул идея Куликово сугышы дәверендә туа башлаган, ләкин ул шул дәвер кешеләре өчен, Гумилев шәрехләгәнчә, ап-ачык аңлашылмаган. Нижний Новгород, Рязань, Тверь кешеләре Мәскәү гегемонлыгын кайнар яклаучылар булмаганнар. Хәтта Алтын Урда таркалгач та, Мәскәү кенәзлеге белән беррәттән мөстәкыйль Тверь, Рязань һәм башка кенәзлекләр барлыкка килгән. Ләкин урыс кенәзлекләрен Мәскәү яки Киев канаты астына берләштерү идеясе инде күп кенә башларда чуалган.

Димәк ки, Мәскәү Русияне Алтын Урда белән көрәштә түгел, Алтын Урдада сәяси йогынты өчен көрәштә барлыкка китергән. Чынлыкта исә Мәскәү Алтын Урда тарафыннан тудырылган. Мәскәү үзе дәүләт төзелешендә Киев традицияләрен түгел, киресенчә, татар традицияләрен дәвам иткән, әмма алар мәскәүлеправославиегә төрелгәннәр һәм бу тулы мәгънәсендә Мәскәү Урдасына әверелгән. Бөек мәмләкәтчел караш ияләре — татарларның Мәскәүдә дәүләт хезмәтендә барлыкка килүләре иҗтимагый фикерне Мәскәү гегемонлыгы урнаштыру ягына этәргән.

Мәскәү чыңгызчылар дәүләтчелеге идеясенә таң калган. Удел Русенда хакимлек иткән примитив күзаллаулардан аермалы буларак, Чыңгызның дәүләт идеясе искиткеч зур, һәм ул үзенә тартып торган. Әмма аны әле үзләренеке итеп ясарга кирәк булган. Урыс фикере дини яктан кардәш булган Византия традицияләренә мөрәҗәгать иткән, державачылыкны православие белән бәйләгән, аннары Чыңгыз хан идеяләре бөтенләй яңа, христианлык кабыгына төрелгән, алар инде татар идеяләре түгел (әмма дә ләкин аларның ярым онытылган Византия белән дә тере элемтәсе юк), алар саф урыс идеяләренә әйләнгәннәр. В.О.Ключевский фикеренчә, Византия диннәр һәм сарай мәкерләре эшендә Русия өчен карт укытучы ролен үтәгән, «әмма бөек урыс дәүләте кору башланган мизгелдә ул инде юкка чыккан булган. Хәер, аңа кадәр дә Царьград сәяси яктан Русь өчен яңа гына аякка басып килүче яшь баланы дөрес йөрергә өйрәтүче карт һәм аксак инвалид кебек булган». Тагын бер абруйлы тарихчы В.Ф.Платонов та шундый ук рухта язган: «Безнең бабаларыбыз Византиянең әкренләп үлеп бару процессын игътибар белән һәм озак күзәткәннәр. Бу күзәтү кабатларга омтылу түгел, тискәре сабак кына бирә алган, мавыгу түгел, җирәнү хисе генә тудыра алган». 1441 елда Рязань епискобы Ионаның Константинополь патриархиясе тарафыннан түгел, ә урыс епископлары соборы тарафыннан «митрополитлыкка аталуы» гаять хас күренеш. Шул рәвешле Византия традицияләре Мәскәү экспансиясе башланудан күпкә элегрәк тулысынча өзелгәннәр, символик хатирә булып кына калганнар. Киресенчә, Алтын Урданың дәүләт тәртипләре гадәти һәм көндәлек булган. «Беренче патшаларның үз-үзләренә монгол ханнарының варислары итеп карауларын белгертүче билгеләр бар,— дип яза Ричард Пайпс.— Чиркәү йогынтысында кайчак Византия үрнәген сылтау итсәләр дә, алар үзләрен Византия императорлары дәвамчылары дип атамаганнар... Казанга һәм Әстерханга соңгы һөҗүме вакытында ук инде Иван аларны үз биләмәсе дип атаган; бу бер генә нәрсәне аңлата алган — ул үзен Алтын Урда ханының варисы дип санаган». Алтын Урда мирасыннан баш тарту соңрак, Петр I заманында башланган.

Урыс кенәзлекләрен бердәм державага әйләндерү идеологиясен Псков монахы Филофей бөек кенәз Василий III кә юлламада формалаштырган: «Күзәт һәм аңла, тәкъва патша, чөнки бөтен христиан патшалыгы синең берлегеңә җыелачак, ике Рим җимереләчәк, ә өченчесе (Мәскәү) торачак, ә дүртенчесе булмаячак». Дөньяны шушы рәвешле тою Русьны галәми илгә әверелдергән. Шуның белән бергә, Н.Бердяев сүзләре буенча, «империячел вәсвәсә миссиячелек аңына үтеп керә». Дөньяга яңача караш Русия барлыкка килүне алдан ук билгеләгән, гәрчә нигезенә миссиячелек экспансиясенә хас барлык каршылыкларны салып куйса да. Н.Бердяев болай дип язган: «Мәскәү идеясенең Өченче Рим буларак рухи җимерелүе нәкъ менә шунда ки: Өченче Рим патша кодрәтен, дәүләтнең куәтен күрсәтү дип күзалланган, Мәскәү патшалыгы буларак, соңыннан империя буларак, һәм, ниһаять, Өченче Интернационал буларак төзелгән. Патша Ходайның җирдәге наместнигы дип танылган. Патша җилкәсенә патшалык мәнфәгатьләре турында гына түгел, җаннарны коткару турында да кайгырту салынган. Моны аеруча Явыз Иван тәкрарлаган».

С.М.Соловьев Мәскәү кенәзлеген Русия дәүләтенә әйләндерүнең төп факторы итеп «кенәзләр арасында туганлык мөнәсәбәтләреннән дәүләт мөнәсәбәтләренә күчү»не саный. Аның фикеренчә, шул сәбәпле бу процесслардан татар факторын алып ташларга кирәк булган. Әмма күчеш үзе Алтын Урда үрнәгеннән башка гамәлгә аша алмаган, ул Русияне төзү өчен өлге булып торган. Бүген чын урысныкы дип күрсәтелә торган нәрсәләрнең тамырлары еш кына татарныкы булып чыга. Мәсәлән, собор, ягъни корылтай җыю, урысларны башкалардан аерып торучы нәрсә дип исәплиләр. Николай Бердяев язган: «Собор җыю идеясе,

рухи җыен ясау урыс идеясе булып тора». Чынлыкта исә бу татарлардан алынган. Бу — борынгы татар принцибы һәм ул беренче тапкыр күчмә демократия институты буларак һуннарда ук теркәлгән.

Русиядә беренче земство соборы Явыз Иван кушуы буенча 1548 елда чакырылган. Моңа кадәр «бөтен Русь җирен» җыйнау тәртибе булмаган, чөнки «һәрбер земщина үз кенәзен генә белгән һәм кенәз белән аралашу өчен үз органы — җирле вече җыйган, анда кенәзгә үз ихтыяҗларын җиткергән һәм кенәз дә үз земщинасына үз ихтыяҗларын белдергән. Ни кенәзләрнең, ни җирле земщиналарның бөтен Русь җире фикеренә мохтаҗлыгы булмаган». Күптәнге урыс күренеше булып вечелы удел земщинасы торган, әмма корылтай түгел. Корылтай җыюга ихтыяҗ аерым кенәзлекләрне Мәскәү кулы астында берләштерү белән бергә туган. Явыз Иван, Алтын Урдадан соңгы ханнарның эшен үзләштереп һәм дәвам итеп, типик сәяси коралларның берсен — корылтайны үзенә корал итеп алган.

Казан ханлыгында хан сайлау яки әһәмиятле карарлар кабул итү өчен корылтай чакырылган, урыс чыганакларында ул «бөтен Казан җире» дип аталган. Аның составы турында 1551 елның 14 маенда уздырылган корылтайга карап фикер йөртергә мөмкин, анда Кол Шәриф җитәкчелегендә руханилар (1), Ходайкол җитәкчелегендә угланнар (2), «олы карачи» Нур Гали Ширин җитәкчелегендә кенәзләр һәм морзалар (3) җыелган. Гадәттә, хан сайламаган очракта, корылтай башында хан үзе торган. Шул рәвешчә корылтай өч катламның — руханиларның, гаскәриләрнең һәм җир игүчеләрнең җыелышы булган. Әмма кайвакыт шулай ук «казаклар», ягъни гади сугышчылар, «тарханнар» (өстенлекләргә ия кешеләр) һәм чит кешеләр дә катнашкан. Корылтай ханны алып ташлый алган, 1551 елда Сафа Гәрәйне тәхеттән нәкъ шулай төшергәннәр. Җангалине сайлаганда, урыс хөкүмәте «бөтен Казан кешеләренең» Русия белән берлеккә тугры булырга ант итүләрен таләп иткән. Шулай итеп, урыслар бу сәяси институтны бик яхшы күзаллап кына калмаганнар, шартнамәләр төзегәндә яки Казан тәхетенә үз кешеләрен куйганда аннан актив рәвештә файдаланганнар да.

Икенче земский соборның хөкем грамотасыннан күренгәнчә, Русь җире вәкилләре түбәндәге төркемнәргә бүленгәннәр: «руханилар төркеме, боярлар, окольничийлар һәм дәүләт дьяклары төркеме, беренче статья дворяннар төркеме, Торопецк алпавытлары төркеме, Луцк алпавытлары төркеме, дьяклар һәм приказ кешеләре төркеме һәм кунаклар төркеме». 1613 елгы соборны түбәндәгеләр тәшкил иткән: 1) рухани хакимият; 2) сарай чиннары; 3) Мәскәү дворяннары; 4) шәһәрләрдән сайлап куелганнар яки вәкаләт биргәннәр, руханилар, дворяннар, казаклар, посад һәм уезд кешеләре. Корылтай тәшкилияте белән бертөрле булуы күзгә үк ташланып тора. Соборларның функцияләре дә корылтайларныкы кебек үк: соборлар закон чыгаруга, салымнарга, шулай ук патшалар сайлап куюга бәйле иң әһәмиятле гомуми мәсьәләләрне хәл иткәннәр. Поляклар ябырылуыннан соң собор җыю буенча грамотада болай диелгән: «Мәскәү Польша һәм Литва кешеләреннән чистартылды, Ходай чиркәүләренә элеккеге матурлыгы кайтарылды һәм Ходай исеме аларда элеккечә дан казана, ләкин Мәскәү дәүләтенә патшасыз тору ярамый, аның турында һәм Ходай кешеләре хакында кайгыртучы булмый: патшасыз калса, Мәскәү дәүләтен туйганчы бөлдерәчәкләр, патшадан башка дәүләт берничек тә төзелми, караклар тарафыннан берничә өлешкә бүлгәләнә, һәм караклык арта бара...» Борис Годуновны, Михаил Федорович Романов-Юрьевны да земский соборларда сайлап куйганнар. Бөек Петр исә үзен собор сайлап куйган булса да, үзе патшалык иткән чорда аны бер тапкыр да җыймаган. Гомумән, ул татар мирасына тискәре карашта булган, ә Екатерина II исә соңгы земский соборны җыйган. Шуның белән ханнарның (патшаларның) сайланып куелу һәм гомумдәүләт мәсьәләләрне корылтайларда (соборларда) хәл итү тарихы тәгәлләнгән. Хәер, XVIII гасырда әлеге институт архаик булып күренгән. Аны бетерү акланырлык күренеш, әмма аны бөтенләй алып ташламаска, ә заманчарак коллектив органга алмаштырырга кирәк иде. Әлеге органның абруйлы, вәкаләтле җыелышка әверелүгә омтылышы сизелгән, ә бу исә Русиянең сәяси язмышын үзгәртә алган булыр иде, ләкин Петр үзен император дип игълан иткән, ул сайлап куя һәм күзәтчелек итә торган органга мохтаҗ булмаган.

Шулай итеп, Киев Русе ул асылда Русия түгел. Аларның географик, сәяси-хуҗалык һәм этник эчтәлекләре бөтенләй үзгә. Киев православиене кабул иткән һәм аны урыс тормышына керткән. Киев — урыс культурасы чыганакларының берсе, әмма Русия үзе Алтын Урда ханнары белән дуслык аркасында ныгыган Мәскәүдән башлана. Шуңа күрә XVII гасырда Русиянең Украина белән «яңадан кушылуы» дигән төшенчәнең идеологик штамптан гайре бернинди дә мәгънәсе юк. Бу Литва белән Польша кысаларында үсүче Малороссиянең Мәскәү дәүләтенә кушылуы булган. Моннан Украина белән бүгенге вазгыять тә аңлашыла, аның Русия белән каласы килми, ә менә татарлар үзләрен башкача тоталар, алар аерылып чыгуга омтылмыйлар, алар Русияне чит итеп түгел, үз дәүләтләре итеп кабул итәләр. Бу чыннан да шулай.

Әмма Мәскәү Русен да ни географик, ни сәяси, ни этник мәгънәдә Русия дип атап булмый әле. Русияне Мәскәү Русеннан тарихи урыс кенәзлекләре кысаларыннан чыгучы территориаль экспансия аерып тора. Русия Мәскәү тарафыннан урысныкы булмаган яңа территорияләр басып алына башлагач ук барлыкка килә. Мәскәүнең иң беренче җитди җиңүе — 1552 елда Казан ханлыгын — беренче чит һәм православиеле

булмаган дәүләтне буйсындыру. Моңа кадәр Московия, Мәскәү Русе, Бөек Мәскәү кенәзлеге була, ләкин Русия түгел. Казанны алганнан соң яңа дәүләт барлыкка килә. «Татар патшалыгын» яулап алганнан соң,— дип яза С.М.Соловьев,— «Русьта, ниһаять, патша барлыкка килә». «Урыс җире» дип аталган нәрсә Русия яки, Н.М.Карамзин сүзләре буенча, «яңа Русия» була. Бу әверелеш Алтын Урдадан соңгы дәүләтләрнең Евразиядә калган татар мирасы өчен көрәше нәтиҗәсендә килеп чыккан. Кенәз Н.С.Трубецкой гаять катгый белдергән: «Мәскәү дәүләте татар изүе аркасында барлыкка килгән. Мәскәү патшалары, «Русь җирләрен җыюны» төгәлләгәнче үк, бик күпкә алдан Бөек монгол монархиясенең көнчыгыш олысы җирләрен җыя башлаган: Мәскәү Казанны, Әстерханны һәм Себерне яулап алганнан соң гына куәтле дәүләткә әйләнгән. Русь патшасы монгол ханының варисы булган. «Татар изүен бетерү» татар ханын православный патшага алмаштыруга һәм хан сараен Мәскәүгә күчерүгә генә кайтып калган. Хәтта Мәскәү патшасы боярларының һәм патша хезмәтендәге башка кешеләренең әһәмиятле процентын татар аксөякләре тәшкил иткән». Бүгенге көндә бу гаять сәер яңгырый, ләкин XVI гасырда мондый күзаллау бик табигый булган. Белек Булат Явыз Иванга болай дип язган: «Белек Булат морза христиан патшасы Ак патшага күптин-күп баш ия... Теге җирдә ул Чыңгызның турыдан-туры улы дип әйтелә һәм турыдан-туры патша дип атала. Ә бу җирдә мин Идегәй улы дип аталам... Абыем Дәрвиш патша белән Чыңгыз улы Ак патшаның, православный һәм рәхимле Ак кенәзнең аягына егылырга барабыз». Нугай бәе Явыз Иванга аны Чыңгыз ханның турыдан-туры дәвамчысы дип атап мөрәҗәгать иткән: «Бөек Чыңгыз патшаның турыдан-туры нәселе булган бәхетле патша син... Теләсәң — рәхимлек итәрсең, теләмәсәң — рәхимлек итмәссең». Тарихка бүтәнчә караш күпкә соңрак, урыс патшаларының һәм татар ханнарының дәвамчылыгына ишарәләрнең теләсә кайсысын җимереп барган Петрдан соң барлыкка килә.

Казанны яулап алу Русия тарихында борылыш ясаучы факт булган. Иван III хатларда кайчак үзен патша дип атаган, тик моны халыкара дәрәҗәдә берәү дә танымаган һәм ул Польша-Литва илчеләренә король Сигизмунд аның титулларын һәм хокукларын танымый дип зарланган, ә Явыз Иван патша титулын тулысынча законлы кабул иткән, чөнки ул ханлык яулап алган, ә патша титулы хан титулына тәңгәл килгән.

Алтын Урда Европа һәм Азиянең күп халыклары язмышына зур йогынты ясаган. Ул көрәшеп алырга лаеклы, данлы мирас булган. Казан ханлыгын Московиягә кушкач, әлеге мирас өчен көрәштә җиңүче билгеләнгән. «Казанны алуның якындагы сәяси һәм идеологик нәтиҗәләре ике төрле,— дип исәпли Ярослав Пеленский,— тыштан караганда аларны Иван IV нең урыс хакиме титулына өстәп «Казан патшасы», бераз соңрак «Әстерхан патшасы»титулларын алуында күрергә мөмкин, алар Мәскәү дәүләтенең үзгәрешләрен чагылдыралар. 1552 елга кадәр барыннан да элек ул Бөек урыс дәүләте буларак яшәгән. Шушы яңа титулларны алгач, Иван IV Алтын Урда дәвамчылары булган дәүләтләрнең тәхетләренә, димәк, Алтын Урданың үзенең тәхетенә хокукын раслаган». Шушы вакыттан алып Русиянең үз тарихы башлана, ул татар таҗларын горурлык белән үзенең гербына кертә.

Борис Ельцин «Русиянең дәүләт гербы. 500 ел» күргәзмәсен ачу хөрмәтенә юлламасында Мәскәүнең бөек кенәзләре тарафыннан ике башлы бөркет гербы кабул ителү «Русиянең ике гасырлык бәйлелектән азат ителүен» чагылдыра дип белдерде. Бу тезис хәтта шикле генә дә түгел. Бөтенләй киресенчә: нәкъ менә шушы герб Русиянең Алтын Урда дәвамчысы булуын гәүдәләндерә дә инде.

Ике башлы бөркет төрле заманнарда төрле халыкларда очрый: Борынгы Мисырда, Кече Азиядә, Рим империясендә, Сасан дәүләтендә, гарәп дөньясында, Көнбатыш Европада. Византиядә ике башлы бөркет дәүләт билгесе буларак XIV гасырдан башлап телгә алына.

Русия гербында ике башлы бөркетнең барлыкка килүен гадәттә Византиягә бәйлиләр. Аны Византиядән Иван III кә кияүгә чыкканда Софья Палеолог алып килгән, имеш. Икенче бер фараз моны Иван III нең император хакимиятенең бизәлеш элементларын Көнбатыш Европа илләреннән, атап әйткәндә, Габсбургглардан күчерүе белән бәйли. Әмма моны башкача аңлату табигыйрәк. Ике башлы бөркет Византиядә барлыкка килгәнгә кадәр бик күпкә элегрәк Алтын Урдада киң таралган булган. Ул Җанибәк хан акчаларында еш очрый. Алтын Урда ханнары бу символны каян алганнардыр — әйтүе кыен. Аның ниндидер монгол символы булуы мөмкин яки ул гарәпләрдән күчерелгәндер, бусы да гаять табигый хәл. «Мөселман акчаларында,— дип яза С.А.Янина,— ике башлы бөркет сурәте XII — XIII гасыр башында ук Зәнгиләрнең һәм Ортукларның чүкелмәләрендә очрый. Соңгыларыннан әлеге эмблеманы Хулагучылар алган, моны Ирбиль чүкелмәсендәге 678 елгы (безнең эраның 1279 — 1280) акчалардагы сурәтләр раслап тора. Византия сфрагистикасында ике башлы бөркет XIV гасырның икенче чирегендә генә, император Андроник (1325 — 1343) заманында барлыкка килә, ә акчаларда исә XIV гасырның икенче яртысында гына Трапезунд Комненнарында — Алексей III тә (1349 — 1390) һәм Мануил III тә (1390 — 1417) барлыкка килә». Алтын Урданың үз акча янчыкларында яткан һәм ил буенча озак еллар йөргән акчаларыннан күптән таныш булган сурәтне Византиядән алу урыс кенәзләре өчен сәер гамәл булыр иде.

Соңрак, XVII гасырда, ике башлы бөркет өстендә өч таҗ барлыкка килә, алар Русия дәүләтенең нигезләрен чагылдыралар. Ватан тарихы энциклопедиясендә язылганча, «Патша Алексей Михайлович беренче тапкыр дәүләт гербы рәсемен ясарга кушкан. 1625 елда гербка буйсындырылган өч бөек патшалыкны — Казан, Әстерхан һәм Себерне белдерүче өч таҗ кертелгән». Ул заманда татар мирасын үзләштерү горурлык һәм халыкара абруйны күтәрү булып саналган.

Русиянең ике чыганагы турында сөйләү тулысынча гадел: тәкъдир ителерлек хезмәте православиене кабул итү булган Киев Русе һәм урыс җирлегенә экспансия, державачылык рухы керткән Алтын Урда. Н.А.Клепинин болай дип язган: «Русьта дәвамчылыкның ике сызыгы, аның ике мирасы турында сөйләргә мөмкин: «Византия белән Киев мирасы» һәм дә «Чыңгыз хан мирасы». Бу мирасларның берсе кире кагылган очракта урыс тарихына караш берьяклыга әйләнә, аның дәүләти яшәешенең бар тулылыгын колачламый...» Тарихи хакыйкать нәкъ менә шушы сүзләрдәдер, мөгаен. Русия татарлардан һәм башка халыклардан күп нәрсә алган, бу мирас, субкультура буларак, күзгә күренеп яки күренмичә генә урыслар менталитетына тәэсир итеп, хәзергәчә аның эчендә яшәп килә. Гоголь юкка гына язмаган: «...һәрбер урыста татар утыра».

О, Русь моя! Жена моя! До боли
Нам ясен долгий путь!
Наш путь —
стрелой татарской древней воли
Пронзил нам грудь.

*А.Блок. «На поле Куликовом»*

Алтын Урда традицияләре Русия тормышында озакка тамыр җәйгән. Алтын Урданың күп кенә законнары һәм культура элементлары шулкадәр нык булганнар ки, алар Петр I дәверенә кадәр яшәгәннәр. Хәзерге заманның кайбер тикшеренүчеләре Русия сәяси культурасының тискәре чалымнары чыганакларын нәкъ менә Алтын Урда традицияләрендә күрәләр. Әлбәттә, болай дип раслар өчен нигезләр бар, чөнки сәяси институтлар дәүләт таркала башлаган вакытта, алар тулысынча бетүгә барганда үзләштерелгәннәр. Мәскәү үзенә идарә итү ысулларын, салым системасын, корылтайны, татар баскакларының эшлекле һәм көнкүреш телен алган. Алай гына да түгел, Явыз Иван хәтта хан (патша) эшчәнлегенә күзәтчелек итүче дүрт бәк һәм корылтай кебек номиналь институтларны да кире каккан. «Ул чиксез хакимияткә берүзе ия булырга теләп кенә калмаган, аның бер кеше хакимиятен киләчәк өчен нык һәм какшамас итеп беркетеп каласы да килгән. Ул бер кеше хакимиятенә каршы тоелган, нindidер мөстәкыйльлек сиземләнгән бар нәрсәне җимерә башлаган. Ул кешеләрне бөтен гаиләләре белән яндырган, җәзалаган һәм газаплаган, кансыз төстә юкка чыгарган, исеме чикләнмәгән хакимият өчен бик күп күңелсез хатирәләргә бәйле булуы аркасында Новгород шәһәрен канлы суешка хөкем иткән; ул үзенең башбаштаклыгын барыннан да өстен куйган, чиркәүнең үзен үк башкалар өчен тыелган нәрсәләрне үзенә рөхсәт итәргә мәҗбүр иткән, чикләнмәгән хакимият тирәсендә үзенә яңа хезмәтчеләр туплаган, алар үзләренең күтәрелүе өчен нәселләренә түгел, бары тик аңа гына бурычлы булганнар һәм үз хезмәтләрендә бары тик аның ихтыяры буенча гына эш иткәннәр. Ул биргән барлык үлем җәзалары тыныч кына үтеп барган, чөнки самодержавиене чикләргә теләүчеләр аз булган, ә халыкның хакимиятне теләсә нинди бүлгәләүгә каршы күргән һәм теләсә нинди катлаулылыкны, үзара бәйлелекне чит иткән бик зур өлеше — барыннан да бигрәк тышкы куркынычсызлыкка мохтаҗ һәм моңа азмы-күпме дәрәҗәдә бер кеше хакимияте астында гына ирешеп булганлыгын гасырлар буена аңлап килгән бик зур өлеше — чикләнмәгән хакимият ягында булган, бу зур өлеш шушы бер хакимияткә һичсүзсез, уйлап-нитеп тормыйча буйсынып, язмышын аның ихтыярына мәңгегә тапшырган, күкләр билгеләгән шушы бер кеше өчен яшәргә, аныкы булырга теләгән». Соңрак исә номиналь роль уйнаучы собор да артык институт буларак кире кагылган, һәм чикләнмәгән хакимият белән крепостное право тантана иткән. Н.Бердяев, урыс тарихында биш чор (Киев Русиясе, татар изүе чоры, Мәскәү, Петр һәм совет заманнары) билгеләп, «Мәскәү чоры урыс тарихында иң начар чор булган, ул иң тынчу, үз тибы буенча күбесенчә азиат-татаррак. Моны аңлап җиткермәү аркасында ирек сөюче славянофиллар аны идеальләштергәннәр. Киев һәм татар изүе чорлары яхшырак булган, аеруча чиркәү өчен һәм, әлбәттә, ике башлангычлы, таркау чор — Петербург заманы яхшырак та, әһәмиятлерәк тә, анда урыс халкының иҗади даһилыгы ныграк ачылган» дип санаган. Язмыш ирониясе буенча, Алтын Урда традицияләреннән саф урыс сәяси культурасына таба һәр адым ирекне киңәйтү ягына түгел, ә башбаштаклыкны принцип буларак ныгытуга илткән. Башбаштаклык деспотчылыкта чагылган, аннан соң фетнә кузгала торган булган. Русиядәге бәла-казаларның сәбәпләрен татарлардан, поляклардан, католиклыктан, Көнбатыштан яки атлантчылардан эзләргә кирәкми, алар сәяси культура нигезенә салынганнар.

Фетнә чорларында, инстинктлар котырынган вакытларда урыс үзаңы күп сынаулар аша узган, ул бунтлар һәм революцияләр барышында ныгый алмаган, ул дәүләттә тынычлык һәм мәгърифәт булганда гына ныгыган. Дәреслекләрдә еш кына XVII гасыр чоры турында мондый тонда язалар, имеш: «Фетнә Русиянең мөстәкыйль тарихи язмышын барлык катламнар тарафыннан да патриотик аңлауны кискенләштергән». Моны «Польша интервенциясе» белән көрәшкә бәйлиләр. Чынлыкта исә Фетнә чорында төрле катламнарның максатлары да төрле булган, моңа Польша белән уния яки Швеция белән берлек төзү дә кергән. Ул чорда патриотик үзаң турында, гомумән, сүз алып бару да кыен. Кузьма Минин һәм кенәз Пожарский дәүләтчелекне яклау идеясеннән бигрәк көнкүреш ниятләрдән яки хәтта икътисади мәнфәгатьләрдән чыгып эш иткәннәр. «Кәсепләре һәм эшләре Мәскәүгә һәм Русьның урта өлешенә табигый бәйләнгән сәүдә шәһәрләре, мәсәлән, бай Вологда, Ярославль, Нижний дәүләт тәртибе зарурлыгын барыннан да элегрәк һәм тирәнрәк аңлаганнар,— дип язган Николай Костомаров.— Шуңа күрә урыс халкының соңгы тапкыр баш күтәрүе дә Нижнийда яралган, бу шәһәрдә ул чакта мул тормышлы берничә капиталист һәм сәнәгатьче булган, алар зирәк рәвештә төшенеп алганнар: югалган малны яңадан җыярга акча калсын өчен бөтен мөлкәтеңне корбан итү, аны чит ил кешеләренә яки юлбасарларга таларга биреп, үзеңне бернинди мөмкинлекләрсез калдыруга караганда яхшырак». Шәхси икътисади мәнфәгатьләр тәртип торгызу өчен көрәштә көчле нигез булган, өстәвенә сәүдәгәрләр Русия базарында поляклар белән көндәшлектән курыкканнар. Һәм, әлбәттә, гаять зур тоташтыру вазифасын православие башкарган. Патриотик үзаң иҗтимагый аң элементы буларак бөтенләй дә булмаган. Пожарский полякларга каршы ничек рәхимсез булса, казакларга каршы да шулай рәхимсез сугышкан. Әмма урысларны һәм казакларны берләштерүче нәрсә православие булган.

Мәскәү боярлары Польша короле Сигизмундның улы Владиславка өметләнгәннәр. Шуйскийны алып ташлагач, Мәскәү халкы тәртипне Речь Посполитая белән унияне тану аркылы торгызырга уйлаган, әмма алар Владиславның православие кабул итүен таләп иткәннәр. Сигизмундның илчеләре: «Король сезнең гореф-гадәтләрегезне саклап кына калмас, сезнең хокукларыгызны, динегезне, ирекләрегезне, хатыннарыгызны һәм балаларыгызны һәм сезнең мөлкәтегезне саклар. Корольгә хак хәбәрләр килеп җиткән: пычрак төрекләр һәм татарлар, сезнең бүлгәләнгән булуыгыздан файдаланып, безнең җирләр аркылы узып, сезнең җирләрне тартып алыр өчен сезнең чикләрегезгә якынлашалар. Менә шул чакта сезнең борынгы христиан динегезгә һәлакәт киләчәк»,— дигәннәр. Бу сүзләрдән соң Филарет һәм боярлар елап җибәргәннәр һәм җавап биргәннәр: «Бөек Аллабызга рәхмәт укыйбыз, ул иң яхшы королебезгә безнең озак бәлаләребезне һәм газапларыбызны бетерү теләге иңдергән! Без бары бер нәрсә сорыйбыз, бер нәрсә турында гыйбадәт кылабыз: ул безнең православие динебезне, монастырьларыбызны, изге әйберләребезне җимермичә сакласын иде». Алар Сигизмундтан урыс тәхетенә король улы Владиславны утыртуын үтенгәннәр. Поляклар «Тушино карагы»н җиңәргә ярдәм иткәннәр һәм Мәскәү Владиславка ант биргән. Аның артыннан Коломна, Серпухов, Тула, Рязань һәм башкалар да ант иткәннәр. Ул вакытта патриотик аң булмаган. Владислав хакимияте Сигизмунд диктатурасына әверелгәч, полякларга каршы сугыш башланган, милли көрәш сыйфатын алган каршылык күрсәтү менә шул вакытта барлыкка килгән дә инде.

Ул заманда урыслар арасында Мәскәү тәхетенә швед династиясен утырту яклы кешеләр күп булган, гәрчә аларны протестантлык кызыктырмаса да. Алар протестантлыкны католиклык кебек үк латинчылык дип санаганнар. «Патша итеп чит ил кешесен кую күпләргә мөмкин хәл кебек тоелган. Собор җыяр алдыннан гына Пожарский шведлар белән Карл IX ның улы Филиппны сайлау турында сүз йөрткән; нәкъ шулай ук Германия императоры Рудольфның улын сайлау турында сөйләшү башлаган. Ләкин бу берәүләрнең нейтралитетына икенчеләре белән берлеккә ирешү максатында эшләнгән дипломатик хәйлә генә булган. Шулай да Мәскәүдә чит ил кешесен патша итү фикере булган һәм ул нәкъ менә боярлардан чыккан». Мондый карашлар белән беррәттән нигездә мөстәкыйль территорияләргә әйләнгән Псковта, Путивльдә, Аразамаста, Әстерханда ачыктан-ачык сепаратизм хәрәкәте яшәп килгән. Пожарский тарафыннан Казанга җибәрелгән стряпчий Биркин андагы дьяк Шульгин белән, ополчение уңышка ирешә алмас дип санап, үзләренең шәхси хакимиятен урнаштырырга карар иткәннәр, ләкин казанлылар ополчениедә катнашу ягында нык торганнар. Биркин үзе белән бик килешми торган татар башлыгы Лукьян Мясный белән бергә Пожарскийга кушылган. Әмма бернинди дә рәсми вазифа ала алмагач, Биркин Казан кешеләре белән китеп барган, үз кешеләре белән Лукьян Мясный гына калган. Бу вакытта Бөек Новгородта швед хакимияте идарә иткән. Монда нинди патриотизм булсын инде? Бер-берсенә дошман булган төрле сәяси көчләрне православие берләштергән. Төрле көчләрнең баш күтәрүендә һәм берләшүендә байрак булып дини ниятләр торган. Үз гомерен корбан иткән патриарх Гермоген чиркәүләрне, образларны, изге әйберләрне сакларга өндәгән, чөнки аларны поляклар һәм литвалылар мәсхәрә итә торган булганнар. Мәскәүне православие башкаласы буларак яклаганнар, башка дәлилләр икенчел булган.

Теләсә нинди «фетнә» иҗтимагый аңны бүлгәли, ә гомумкыйммәтләр икътисади һәм сәяси үсеш дәверендә генә барлыкка килә. «Польша интервенциясе» җирлегендә урыс патриотик аңы барлыкка килү —

соңрак килеп чыккан идеологик төзелмәләр өлкәсеннән ул. Сүз уңаеннан, «поляклар ябырылуы» үзе этник мәгънәдә шулкадәр чуар булган ки, анда кемнәрнең: полякларның яки литваларның, урысларның яки казакларның күбрәк булуын әйтү кыен, анда хәтта Польша-Литва татарлары да, Кырым татарлары да очраган. Николай Костомаров болай дип язган: «Сигизмундның теләсә кемнән җыелган 12 меңгә кадәр гаскәре булган, шул исәптән Перемышль старостасы Станислав Стадницкий үз дигәнчә йөри торган азгын венгрлар төркемен алып килгән; паннар үз исәпләренә күп кенә сарай командалары китергәннәр; шулар өстенә 2000 кешелек немец җәяүле гаскәре һәм саны 3000 гә кадәр булган поляк җәяүле гаскәре; моннан тыш саны билгеле булмаган Литва татарлары һәм 10 меңгә кадәр Запорожьеның атлы казаклары, алар самопал һәм ук-җәя белән коралланган, кайберләренең озын сцислары (сөңгеләре) да булган. Әмма Польша көчләре моның белән генә чикләнмәгән: гаскәрдә әле теләсә ничек килеп-китеп йөрүче аучылар, гаскәрдә исәпләнмәгән, әмма сугышка яраган олау хезмәтчеләре дә күп булган». Мәскәү ягыннан да көчләр төрле. «Тушино карагы» белән сугышта үз көчләренә ышанган боярлар швед короленең ярдәм сорап мөрәҗәгать итүенә Василий Шуйский исеменнән болай дип җавап биргәннәр: «Безнең патшаның исәпсез-хисапсыз урыс һәм татар гаскәрләре бик күп». Әмма соңыннан король Карл IX һәм Казанда «татарлардан һәм башкортлардан» ополчение җыйган Шереметьев арасындагы килешү буенча аның өметләре нәкъ менә шведларга бәйле булган. Ә «Тушино карагы» башлыча казакларга таянган. Бер яктан — поляклар, икенче яктан урыслар тасвирланса, бу картина дөреслектән ерак булыр иде. Шунысы кызыклы: татарлар әлеге вакыйгаларда кайвакыт мөстәкыйль һәм әһәмиятле роль уйнаганнар. Урыс җирләренең Ялган Дмитрий тарафдарларына һәм полякларга таркалуы «карак» үлгәннән соң тукталган, ә бит аны татарлар үтергән. Әлбәттә, моның артында ни сәяси, ни патриотик омтылышлар тормаган, бу бары тик гадел үч алу гына булган. Касыйм патшасы Үрмәмәтне «карак» ау вакытында поляклар файдасына хыянәт иткәне өчен үтергән. Үрмәмәтнең дусты — керәшен татары Петр Урусов Касыйм патшасын үтергәне өчен «карак»ны йөзенә бәреп битәрләгән. Ә татарлар исә барысы да Урусовны яратканнар. Бервакыт «карак» чанада бара икән, берничә тапкыр туктап, кычкырып, үзенә шәраб бирүләрен сораган, татарлар исәнлегенә эчкән. Аны озатучылар атка атланып кырыйдан барганнар. «Карак» артыннан шулай ук атка атланып барган Урусов кинәт кенә үзенең аты белән чананы кысрыклаган һәм «карак»ка кылычын кадаган: чананың икенче ягыннан Урусовның энесе шул ук мизгелдә «карак»ның башын чабып өзгән. Боярлар тавыш куптарганнар; ә татарлар аларга каршы кылыч күтәргәннәр. Боярлар азрак булган, алар куркуга төшеп кычкырганнар: «Кичер, кичерегез!» Хәбәрләрнең бер төрлесенә караганда, татарлар үз патшачыгын озатып баручы урысларның кайберләрен үтергәннәр; бүтән хәбәрләр буенча исә, киресенчә, Урусов аларның берсенә дә кагылмаска кушкан. Ялган Дмитрий хатыны Марина Мнишек ире өчен үч алуларын үтенеп Дон казакларына мөрәҗәгать иткән. «Аларның башлыгы Заруцкий Маринага битараф булмаган. Ул казакларны һөҗүмгә рухландырган; алар Калугада очраган татарларга һөҗүм иткәннәр һәм 200 гә кадәрен үтергәннәр». Ләкин эш эшләнгән инде. «Карак»ның үлеме фетнә дәверендә борылыш ясаган һәм Сигизмунд өчен начар вакыйга булган дип нәтиҗә ясый Николай Костомаров.

Николай Костомаров — урыс тарихының әлеге чорын тикшерүчеләрнең иң яхшыларыннан берсе — фетнәнең төп сәбәбе итеп Көнбатышны, Польша йөзендә латинчылыкны санаган. Әмма Польша короле Сигизмунд урыс эшләренә кысылган, фетнәнең иң кызган чагында Василий Шуйский 1609 елда шведларны ярдәмгә чакырган һәм шуның аркасында үзенә Польша белән сугыш китереп чыгарган. Чөнки Сигизмунд үзенең швед таҗын законсыз тартып алдылар дип санаган һәм Швеция белән берлектә булган теләсә кемне үзенең дошманы итеп күргән. Полякларның Ялган Дмитрий I гаскәренә катнашуы дәүләти түгел, ә ирекле гамәл булган. Ялган Дмитрий I нең урысларга һәм казакларга таяну дәрәҗәсе һич тә кимрәк түгел. Р.Г.Скрынников билгеләвенчә: «Русиядә Ялган Дмитрийның яллы гаскәре беренче уңышсызлыклардан соң ук таркалган. Отрепьевны тулысынча җиңелүдән ирекле казакларның һәм Төньяк җирнең баш күтәргән халкы гына коткарып калган». Хәер, танырга кирәк ки, иезуитлар һәм Рим Папасы Русьта католиклыкның киң таралуына һәм хакимлеккә ирешүенә зур өметләр баглаганнар. Фетнә тышкы яктан әзерләнмәгән, ул — Мәскәү дәүләтендәге сәяси вазгыять нәтиҗәсе. В.О.Ключевский сүзләре буенча, Ялган Дмитрий «Польша мичендә пешерелгән генә, ә камыры Мәскәүдә ачытылган».

Казаклар фетнәне хәрәкәтләндерүче актив көч булганнар. Н. Костомаров үзе язганча, казаклар үзләренә «дәүләт тормышының агымдагы тәртибеннән бар канәгатьсезлекне» сеңдергәннәр, «һәм үз каршылыкларын халыкка нииндидер хокуклар алуга омтылу белән дә, җәмгыять строенда аңлы рәвештә уңай үзгәрешләр таләп итү белән дә түгел, ә урыс кешесен дәүләти бурыч һәм вазифалар хакына изүе мөмкин булган бар нәрсәгә каршы билгесез һәм аңсыз дошманлык белән белдергәннәр. Шуңа күрә казаклар үзләрендә гражданлык җәмгыятенең бернинди дә идеалын үстермәгәннәр, тигезлекне һәм ирекне чамадан тыш гомуми, башлангыч һәм тоник рәвештә тою белән чикләнгәннәр». Русьның һәм Польшаның кырый (украинный) шәһәрләрендә хакимияттән, талаулардан, изүдән ризасыз булган качак холоплар һәм крестьяннар

тупланган, җинаятьчеләр һәм маҗара эзләүчеләр җыелган. «Кырый җирләрнең иркен тормыш-көнкүреше әкияткә тиң булган; кырыс тормыш анда изү сурәтендә күренгән. Анда дәүләт строе астында тынышмыйча, тормышның башка строен эзләүче ниятләр кайнап торган, шуңа күрә кырыйчылар (украинлылар) Мәскәүгә каршы күтәрелгән яңа байракка бик җиңел ияргәннәр. Бу байрак астына басу күпләрнең күңелен җәлеп иткән, чөнки алар бирелдә табыш мөмкинлеге күргәннәр — аларның аз гына булса да иске Русь исәбенә яхшы яшәп каласылары, аның байлыкларын бүлешеп, файда күрәселәре килгән. Кырый шәһәрләр янында ук бер яктан — Дон, икенче яктан Днепр казаклары яшәгән. Алар барысы да бер сызгырудан соң ук төньякка таба барырга һәм фетнә башлар өчен кырый шәһәрләр ягына басарга әзер торганнар». Иреклe казакларның «фетнә» аңы (монда «Польша качакларын» да өстәргә мөмкин) фантазиянең котыруына китергән. Ялган Дмитрийлардан соң казакларда Петр барлыкка килгән. Аннан соң тагын бер Петр килеп чыккан. «Петрның җиңел кулыннан кыю егетләр үзләрен патшаларның дөньяда булмаган уллары исемнәре белән атый башлаганнар. Әстерханда патша улы Август килеп чыккан; кемдер үзен Иван Иванович дип атаган, имеш, Колтовская дигән хатыныннан улы; аннан соң шунда ук патша улы Лаврентий барлыкка килгән һәм үзен әтисе тарафыннан үтерелгән Иван Ивановичның улы дип белдергән. «Поляк тирмәләрендә», ягъни казак торaклары янәшәсендәге кырларда патша уллары Федор, Ерофей, Клементий, Савелий, Семен, Василий, Гаврило, Мартыннар килеп чыккан, алар үзләрен патша Федор Ивановичның уллары дип атаганнар. Әмма бу уллар өрәкләр сыман юкка чыга барганнар». Тер казаклары үз кешеләрен чыгарырга уйлаганнар. Патша улы итеп Митьканы сайлаганнар, әмма ул беркайчан да Мәскәүдә булмаганлыгын сылтау итеп, баш тарткан. «Һәм казаклар патша улы итеп Муромнан Коровин улы яшь казак Илейка Ивановны атаганнар, аңа урыс башкаласында булырга туры килгән икән. Илейканың атасы посад кешесе Иван Коровин булган. Анасы Ульяна Илейканы «никахсыз» тапкан, законсыз туган бала буларак, ул тормышта кимсетүләрне дә, мохтаҗлыкны да татыган. Илейка берничә ел Идел буйлап йөрүче судноларга хезмәткә ялланган, аннан соң воевода С.Кузьминның җилкәнле агач судносына (струг) эшкә кергән һәм аның белән Терекка китеп барган. Укчы булып кергәч, Илейка 1604 елның җәендә воевода Бутурлин белән Кавказга,«Татаркага шекваль походына» барган. Поход Бутурлин гаскәренең кырылуы белән тәгәлләнгән һәм, яшәүгә бернинди чарасыз калган Илейка Муромец, походтан кайткач, үзен кабалага биргән, холоплыкка кергән — «Григорий Елагин сараена приказланган. Холоплыкта кышны уздырган да Әстерханга качкан». Анда аны Идел һәм Дон казаклары үзләренә алганнар. Патша тәхетенә дәгъва кылучыларның берсенең типик биографиясе әнә шундый. Фетнә Польшадагы, Литвадагы һәм Мәскәү дәүләтендәге стройдан ризасызлыкка җавап буларак килеп чыккан. Казаклар фетнә заманының төп фигурасы сыйфатында Гермогенны чыгарганнар. Ул яшьлеген Донның ирекле казаклары арасында үткәргән һәм руханилар катламына шактый соң күчкән. «60 яшендә Казан митрополиты булып алган Гермоген чит Казан иленә православиене сирәк очрый торган фанатизм белән кертә башлаган». Шуннан соң ул патриарх булган, халыкны ополчение оештырырга өндәгән һәм шуның өчен поляклар тарафыннан җәзалап үтерелгән.

Алтын Урдада ук сәяси формаларның үзгәргән вазгыятькә туры килмәвенә җавап рәвешендә барлыкка килгән казак качкынлыгы Русьта да дәвам иткән. Качкынлык нәсел-чыгыш ягыннан тигезлеккә, язылган законнарның булмавына, хакимиятнең һәм судның сайланып куелуына нигезләнгән. Болар барысы да Мәскәү дәүләтенең түбән катламнарында киң яңгыраш тапкан. Шуңа күрә фетнәнең тирәнтен сәбәбен дәүләт строе белән канәгатьсезлектән, деспотчылыктан, көчләүдән һәм башбаштаклыктан эзләргә кирәк. Фетнә деспотчылыкны үзенең чиксез хакимиятенә әйләндергән Явыз Иван вакытында ярала башлаган, ә Борис Годунов исә кайбер хәлләр аркасында вазгыятьне яхшырта алмаган. «Барлык урыс кешеләре чикләнмәгән хакимиятле дәүләтнең үз җилкәләрен баскан төрле авырлыкларыннан берьюлы азат булу өметен тойганнар; кенәзләр һәм боярлар — патша янавыннан һәм җәбереннән; дворяннар, бояр балалары һәм, гомумән, дәүләт хезмәтендәгеләр — аз түләүле хезмәттән; посад һәм крестьян халкы — җигелүдән, талаулардан, таяклардан, эшләрдән, җәфалардан, кабаладан һәм, гомумән, башка барлык ирексезләүләрдән. Шул сәбәпле урыс кешеләре әле Тушино Дмитриена, әле Шуйскийга кача башлаганнар, ә башкалары бүтән патша уллары янына җыелганнар — барысы да үзләренә ташламалар эзләгәннәр, ягъни дәүләтнең җимерелүен аңсыз рәвештә теләгәннәр». Фетнә чыганагын Көнбатыштан эзләү белән чагыштырганда, Костомаровның бу сүзләрендә дөреслек күбрәк.

Минин һәм Пожарскийга кадәр беренче ополчениене Прокопий Ляпунов җыйган, аны казаклар үтергәннәр, ләкин земщина нык торган. Казаннан Пермьгә болай дип язганнар: «Митрополит һәм Казан дәүләтенең татарлар, чувашлар, чирмешләр, вотяклар белән барлык кешеләре Нижний Новгород, Идел буе шәһәрләре белән килешенеп карар иттеләр: Мәскәү һәм Казан дәүләтләре өчен нык торырга, бер-беребезне таламаска, воеводаларны, дьякларны һәм приказ кешеләрен алмаштырмаска билгеләсәләр, яңаларын кабул итмәскә, казакларны кертмәскә, Русия державасының барлык җирләре патшасын сайларга һәм казаклар үзләре генә сайлап куйган патшаны танымаска». Минин һәм Пожарскийның поляклар белән сугышканчы ук

казакларны тар-мар итүләре очраклы хәл түгел. «Вазгыять кенәз Пожарский алдына беренче чиратта казаклар белән сугышны куйган: казаклар үзләре үк Нижний Новгород кешеләренә каршы хәрби хәрәкәт башлап җибәргәннәр. Урыс кешеләренең үзара сугышлары поляклар һәм литвалар ягыннан бернинди комачаусыз 1612 ел буе диярлек барган. Башта Пожарский казакларны диңгез буеннан һәм Идел буеннан куып чыгарган һәм Мәскәү янына чигендергән. Анда, Мәскәү астында, алар зыянсыз гына түгел, Пожарский максатларына хәтта файдалы да булганнар, чөнки башкаланың Польша гарнизонын хәрәкәтсез иткәннәр». Минин һәм Пожарский фетнә тудырган тирәнтен мәсьәләне хәл иткәннәр, ә аннары болганчык дулкында урыс җирләре территориясенә килеп чыккан полякларга каршы сугышка керешкәннәр. Сугышны туктату нәкъ менә казаклар тәкъдим иткән яңа патшаны — Романовны сайлаганнан соң гына мөмкин булган. Тәхеткә күпләр дәгъва кылган: В.И.Шуйский, Воротынский, Трубецкой. Шулай ук патша булырга теләгән Пожарскийны сайлаучыларны сатып алуда гаепләгәннәр. Хәер, елъязмачы раславынча, бу гамәл Пожарскийга гына хас булмаган: «Патша булырга теләгән вельможаларның күбесе күпләрне сатып алдылар, күп бүләкләр бирделәр һәм вәгъдә иттеләр». Михаил Федорович Романов үзе бу процесста актив катнашмаган, Морза Чет төзеткән Ипатьев монастыренда качып утырган. Аның мәнфәгатьләрен туганы Шереметьев кайгырткан. Романовны сайлауны елъязмачылар казакларның басым ясавы белән аңлаталар, нәкъ менә шуңа күрә аның династиясе тынычлык урнаштырган, Романовның тәкъдир ителерлек ниндидер башка хезмәтләре булмаган.

Русиядә деспотчылык сәяси ирекләр белән түгел, ә казак качкынлыгы, үзләштерелмәгән җирләргә качу белән тигезләнгән һәм вакыт-вакыт «фетнә» тудырган. Николай Костомаров болай дип язган: «Безнең фетнәле дәвер бернәрсәне дә үзгәртмәгән, дәүләт механизмына, төшенчәләр тезмәсенә, иҗтимагый тормыш көнкүрешенә, әхлакка һәм омтылышларга бернинди яңалык та кертмәгән; ул дәвер күренешләреннән чыгып урыс тормышы агышын аның өчен уңай яки тискәре мәгънәдә яңа юнәлешкә борып җибәрерлек бернәрсә дә кермәгән... Урыс тарихы, гомумән, гадәттән тыш эзлекле бара, әмма аның акылга муафыйк барышы фетнә вакытын гүя сикереп уза да алга таба үз агышын шул ук элеккеге юлдан, шул ук ысуллар белән дәвам итә. Авыр, фетнәле заманда яңа һәм алдагы чорда хакимлек иткән табигый тәртипкә чит күренешләр булган, әмма алар соңыннан кабатланмаганнар, һәм ул вакытта чәчелгән төсле тоелган орлыклар соңыннан шытып чыкмаганнар». Русия җәмгыяте кризислы вазгыятьтән сабак ала белмәгән һәм, күрәсең, бүген дә белми. Ул Русиянең «табигый» режимы дип даими рәвештә деспотчылыкка мөрәҗәгать итә, ә аннан соң фетнә килеп чыга.

Деспотчылык кабат-кабат яңадан үстерелгән һәм җавап булып «фетнә», бунтлар, революцияләр туган. Бу саф урыс традициясенә әйләнгән, аның татарга бәйле үткән заманга катнашы юк, ул закончалыкка әверелгән. Явыз Иваннан соң «Бөек фетнә» килгән, аннан соң деспотчылык көчәйгән. Бөек Петр император булган, аннан соң сарай түнтәрелешләренең һәм гомуми тәртипсезлекнең бөтен бер чоры башланган, ул Екатерина II гә кадәр дәвам иткән. Екатерина исә гомуми либераль мөгамәләгә кармастан, крепостнойлыкны һәм армияне ныгытуга юнәлдерелгән Петр линиясен дәвам гына иткән. Моңа җавап итеп бунтлар башланган. Пугачев дәүләт нигезләрен какшаткан. Ләкин сәяси система чираттагы крестьян фетнәсенә берничек тә илтифат итмәгән. Александр I самодержавиене ныгыту линиясен дәвам иткән, моңа Наполеонга каршы сугыш ярдәм иткән һәм ил җавап рәвешендә декабристлар чыгышын кичергән, аннан соң народоволецлар барлыкка килгән. Крепостнойлыкны гамәлдән чыгару реформа чарасы булган, әмма ул шулкадәр ятышсыз үткәрелгән ки, нәтиҗәдә крестьяннарның хәле начарланган. Крестьян тормышының җайсызлыгы 1905 елгы революциягә китергән. Аннан соң сәяси ирекләр ягына декоратив ташламалар ясалган, әмма озакка түгел. Революциядән соң биш ел да узмаган — яңадан «хакимият вертикален» ныгыту башланган, һәм 1917 елда кабат фетнә купкан. Сәяси ирекләр 20 нче елларның уртасына кадәр чыдаганнар. 1937 ел аларны тулысынча күмеп куйган. Сталин деспотчылыгы Явыз Иван һәм Бөек Петр режимнарына тиң булган, әмма ул да иҗтимагый үсешнең тарихи юнәлешен үзгәртә алмаган. Совет самодержавиесе артыннан «үзгәртеп кору» килде, аның нәтиҗәсендә СССР таркалды. Бу да сәясәтчеләр өчен сабак булмады. 2000 елдан кабат демократияне чикләүгә, Төньяк Кавказда сугышны дәвам итүгә, федерализмны җимерүгә юнәлеш алынды. Хәзер яңа «фетнә» күтәргә кирәк инде. Русиянең сәяси культурасы үзенең дә, башкаларның да тарихи тәҗрибәсенә колак салмый.

## Бөек борылыш

*О старый мир! Пока ты не погиб,*
*Пока томишься мукой сладкой,*
*Остановись, премудрый как Эдип,*
*Пред Сфинксом с древнею загадкой!*

*Россия — Сфинкс. Ликуя и скорбя,*
*И обливаясь черной кровью,*
*Она глядит, глядит, глядит в тебя,*
*И с ненавистью, и с любовью!..*

А.Блок. «Скифы»

Русия татардан калган мирастан авырсынган. Петр I гә кадәр беркем дә татар традицияләреннән арына алмаган, ә Петр моңа керешкән, асылда, ул шуңа күрә дә бөек реформаторга әверелгән. Европага таба иң беренче Борис Годунов борылган, әмма Көнчыгыштан Көнбатышка таба чынлап торып борылыш Петрдан башланган. Аның үзгәртеп коруларының асылы — Алтын Урданың искергән мирасыннан котылып, дөнья киңлекләренә чыгу, Көнбатышның яңа шаукымнарын кертү, иң элек, әлбәттә, хәрби даирәдә. Петр патша даими армияне, флотны, уңай сәүдә юлларын Европа үрнәгендә төзегән, 200 фабрика һәм завод салдырган, алар өчен уку йортлары ачкан. Ул Европа җитештерүенең күп төрләрен Русия җирлегенә күчергән. Әмма реформаларны ул югарыдан революция ясау ысулы белән башкарган, моңа сәяси системаны бик аз катыштырган, дәүләт корылышы өлкәсендә ул хәтта бер адым артка чигенгән — үзен император дип игълан итеп, земский соборны һәм иректә фикернең беренче чаткыларын юкка чыгарган. Аның шведлар үрнәгендәге административ реформасы исә урыс җирлегенә яраша алмаган.

Петр I һәм Екатерина II, ачыктан-ачык Көнбатышка йөз тотучы монархлар буларак, бар көчләрен урыс халкындагы көнчыгыш тамырларны бетерүгә юнәлткәннәр. Нәкъ менә шул чорда барлык мәгълүм фактларны яңадан карап чыгып, чыганакларны бозып, Көнчыгыш белән бәйле һәрнәрсәне каралтып күрсәтүче рәсми тарих барлыкка килә дә инде. Объектив булсын өчен шуны да әйтергә кирәк: нәкъ менә шул чорда урыс тарихчыларының немец культурасы йогынтысына нык бирелгән фәнни мәктәбе оеша башлаган. «Алар немец тарих мәктәбенең бөтен нәтиҗәләрен һәм карашларын үзләштергәннәр,— дип язган С.Ф.Платонов.— Аларның кайберләре Гегель философиясе белән дә мавыгып киткән, гәрчә Германиядәге төгәл һәм җитди фактларга таянучы тарих мәктәбе Гегельнең һәм аның тарафдарларының метафизик фикер сөрешләре белән бик тату яшәмәсә дә. Шулай да тарихчылар һәм Гегель төп уртак фикергә килгәннәр: тарих — кешелек җәмгыятьләренең закончалыклы үсеше ул». С.М.Соловьев бу алымны Петрга бәя бирүдә беренчеләрдән булып кулланган, ягъни ул, инде билгеләп үткәнебезчә, татар чорын саф урыс яшәү рәвешләре үсешенең «закончалыклы» чылбырындагы ниндидер бер очраклылыкка санап бөтенләй төшереп калдырган. С.М.Соловьев фикеренчә, Русия әхлакый, икътисади һәм административ яктан бөтенләй какшаган булган һәм дөрес юлга кискен реформалар ярдәмендә генә чыга алган. «Халык юлга җыенган һәм юлбашчысын көткән». Бу юлбашчы — Бөек Петр, һәм ул Русияне кризистан алып чыккан. С.М.Соловьев Петрны «үз халкының улы», халык омтылышларын чагылдыручы дип атый, ә бу исә Петрның халыкка каршы ачыктан-ачык сәясәтенә туры килеп бетми. Петр үз ватанына фидакарьләрчә хезмәт итү дәрәҗәсенә күтәрелә алган булыр иде, әмма ул кешеләрне корабльләр төзү өчен кирәкле кораллар сыйфатында кабул иткән. Аның өчен халык — аңгыра һәм инерт масса гына. В.О.Ключевский сүзләрендә дөреслек күбрәк: «Петр рух көчен түгел, хакимият көчен кулланган һәм кешеләрнең әхлакый омтылышларына түгел, инстинктларына исәп тоткан. Поход арбасыннан һәм почта станциясеннән торып дәүләт белән идарә иткәндә, ул кешеләр турында түгел, эш турында гына уйлаган, хакимиятнең көченә нык ышанганга күрә, ул массаларның пассив куәтен чынлап бәяли алмаган». Халык исәбенә халыкка хезмәт итеп булмый. Берсе икенчесен сызып ташлый.

Петр I реформаларына төрлечә бәя бирелә. Яңалыкка омтылучылар аны чиксез-чамасыз күккә чөйгәннәр. Ломоносов аны «Җирдәге Алла» дип атаган. «Көнбатышчылар», Петр аркасында Русия, ниһаять, олы мәйданга чыга һәм урыслар тарихи халыкка әверелә дип санаганнар. Белинский сүзләренә караганда, Петр үз реформасы белән «азиатлар илен» кешелекле цивилизациягә китереп кушкан. Ул заманнарда болай дигәндә герман-протестантлык культурасы күздә тотылган. «Көнбатышчылар» өчен Петрга кадәр Русиянең тарихы да, аңлы яшәеше дә булмаган. Чаадаев исәпләвенчә, Петр инде сизелә башлаган тарихи тенденцияләрне тотып алган һәм дәвам иткән: «Безгә урыс тарихының беренче сәхифәләрендә ачыла торган түнтәрелешне Бөек Петр гамәлгә ашырган. Ул җисемсез исеме генә булган нәрсәләрне үзгәртеп корган, яшәргә сәләтсез нәрсәләрне генә юк иткән, үзеннән-үзе туарга җыенган нәрсәләрне генә булдырган, аңа кадәргеләр башкарырга омтылганны гына башкарган. Безнең фикеребезчә, бу — аның атаклы реформасын һәм аны халыкның хуплап каршы алуын аңлауның акылга сыярлык бердәнбер алымы. Шул халыкның бөтен тарихы үзенең хакимнәре хакына бар нәрсәдән эзлекеле төстә, тоташ ваз кичүдән гыйбарәт икәнен; шул халыкның үз тарихын үз-үзен үзе үк чакырып китергән бер өер Скандинавия авантюристлары хакимиятенә тапшырудан башлап җибәргәнен; аннары үз динен эзләп чит халыкларга юнәлгәнен; соңрак үз илен басып алган кыргый юлбасарларның иң оят йолаларын үзләштергәнен; һәм, ниһаять, әледән-әле төрле-төрле чит җирләр йогынтысына бирелгәнен — боларның барысын да искә төшерсәк, шул халыкны безнең (Европа

күздә тотыла.— *Р.Х.*) цивилизациягә китереп кушкан һәм безнең сәяси система даирәсенә керткән бөек буйсындыру гамәле тагын да табигый күренәчәк...».

Петр дөрес чамалаган: Европа цивилизациясен Русия җирлегенә күчерергә кирәк. Моның өчен аны гаепләргә ярамый, чөнки Көнчыгыштан алырлык нәрсә булмаган, анда регресс хөкем сөргән. Әмма Петрны рәхимсез алымнары һәм берьяклы хәрби юнәлеш өчен гаепләргә кирәк. Ул Европа казанышларыннан кораллар гына алган, ә Европаны алдынгылар рәтенә чыгарган сәяси системаны бөтенләй күрмәгән. Балачагында сәяси тәрбия алмаганга күрә, ул үз Ватаны үсеше өчен сәяси ирекләрнең әһәмиятен аңлый алмаган. Петр Көнбатышта цивилизация түгел, техника эзләгән. Ул коллыкка төшерелгән илдә Европа гыйлемнәре һәм фәннәре таралуны, колның кол килеш инициативалы һәм ирекле булуын теләгән. Дөрес, көчләп тагылган мәгариф системасы ахыр чиктә коллар күңелендә хөррият чаткысы кабызган. Әмма никадәр сәер тоелмасын, мәгариф системасы үзе нәкъ менә хәрби училищеларда иң югары дәрәҗәгә ирешкән, декабристлардан күбесенең коры җир, диңгез, паж, кадет корпусларын тәмамлаучылар булуы очраклы хәл түгел. Хәрби училищелар либераль белем таратучыларга әверелгән.

Остерман сүзләренә караганда, имеш, Петр үзе болай дигән: «Европа безгә берничә дистә елга гына кирәк, аннары без аңа артыбыз белән борылырбыз». Анасы ягыннан — Гольштейн-Готторп кенәзләре, атасы ягыннан Төньяк Германиянең тагын да ваграк Анхальт-Церб нәселеннән булган Екатерина II болай дип әйтү түгел, уйлый да алмаган. Ул Европаның барлык күренекле кешеләре, иң мәгърифәтле философлары белән хат алышкан, гәрчә болай хат язышу Русиянең хөрлегендә берничек чагылмаса да. Аның «Наказ» дигән сәяси манифесты сәяси фикерләүнең ул заманда мәшһүр Европа агымнары рухында булса да, илнең закон чыгару эшендә һәм сәяси гадәтләрендә бернинди дә чагылыш тапмыйча, акыл чарлау һәм Европада үзүзенә реклама ясау булып кына калган. Хокук нигезендә хакимлек итмичә, шәхси хакимиятен урнаштырган Екатерина II Европаның бернинди институтларын да кертергә җыенмаган. «Чиксез генә түгел, билгесез һәм юридик нигездән мәхрүм хакимият — Екатерина заманындагы дәүләт — тарихыбызның төп факты,— дип яза В.О.Ключевский.— Екатерина бу урынчылык фактын югары идарәне закончалыклы итәрлек теләсә нинди омтылышлардан саклаган. Ул әлеге җирле фактны гасыр идеяләре белән томаларга теләгән». Аның дәверендә крепостное право көчәйгән һәм киңрәк колач алган, крестьяннар XVI гасыр холопларыннан әллә ни аерылып тормаганнар, аларны алпавытларның хосусый милке итеп санаганнар. Крепостнойлык көчәюнең нәтиҗәсе буларак шәһәрләр үсеше туктап калган. Крестьяннардан җыела торган салым күләме акылга сыймаслык дәрәҗәгә җиткән. Крестьян восстаниеләре тора-бара олы бер Пугачев бунтына тупланган.

Петр I кебек үк Екатерина II дә тышкы сәясәттә бик өлгер булып чыккан, «анда бөтен халыкка аңлаешлы һәм аңа якын мәсьәләләр хәл ителгән. Поляк һәм татар ул чактагы Русиянең иң мәшһүр дошманнары булган». Урыс тарихчылары билгеләмәсе буенча, Екатерина II заманында Русия «табигый чикләренә» ирешкән. Бу термин никадәр аңлаешсыз булса, шулкадәр үк популяр. Колонизациягә омтылыштан гайре бернәрсә аңлатмаса да, әлеге термин ул чакларда күпләрнең күңелен үзенә тартып торган һәм теләсә нинди яулап алуны аклаган. Билгеле ки, Петр да, Екатерина да чын реформалар үткәрмәгәннәр.

Реформация — иҗтимагый үсешнең котылгысыз баскычы, гәрчә һәр халык аны үзенчә узса да. Моңарчы Алтын Урдадагы шикелле Русиядә дә Реформациягә мохтаҗ вазгыять туган. Европада Реформация тыныч кына узмаган, әмма аның нәтиҗәсендә җәмгыятьтә ирек дәрәҗәсе арткан. Ул Яңарыш чоры тарафыннан әзерләнгән. Ә Яңарыш чоры, үз чиратында, хөр фикер чагылышы булган антик культурадан көч алган. Борынгы грек философиясен мөселман тәгълиматчылары Европа өчен яңадан ачкан.

Реформа һәм Реформация икесе дә бер нәрсә түгел. Реформация дингә генә түгел, Европа җәмгыятенең сәяси һәм икътисади нигезләренә дә кагылган, ireккә, бәйсезлеккә омтылыш уяткан. Шәхес төшенчәсе килеп чыгу нәкъ менә шул дәвергә карый да, чөнки кеше, авыл, шәһәр, дин общинасыннан котыла башлап, ирекле кешегә әверелә барган. Без, Европа цивилизациясе турында сөйләгәндә, һәрчак Реформация дәвереннән башларга тиеш, аңарчы Европа бары тик географик атама гына булган.

Петр аерым реформалар башлап караса да, Реформациянең асылына төшенә алмаган. Петр реформаларының ярым-йортылыгы соңыннан сәяси традициягә әверелгән. Ул тупикка керткән аграр мәсьәлә аннан соң килгән буыннар тарафыннан да хәл ителмәгән һәм бүгенге көнгә кадәр төп мәсьәлә булып кала бирә. Петр башлаган индустриальләштерү армияне яңадан коралландыруга юнәлдерелгән. Петрдан башлап Русиядән һич аерылгысыз казарма рухы урнашкан. Бөтен икътисад армия һәм флот ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә күчкән, медицина күбрәк хәрби хирургия нигезендә үсеш алган, фармакология яралыларны дәвалауда гына уңышка ирешкән. География һәм этнография, лингвистика, хәтта дини гыйлем дә яулап алу максатларына хезмәт иткән. Петр һәм аның варислары сәяси ирекләр турында уйламаганнар гына да түгел, алар бу ирекләргә ачыктан-ачык каршы торганнар.

Хәзерге заманда Петрны аның шәхси энергиясенә карап түгел, ә бүгенге дәүләтчелек халәтеннән торып бәяләргә кирәк. Русия күп гасырларга сузылган авыр социаль экспериментлардан соң үз карашын кабат Көнбатышка юнәлтте, ул XVIII гасырдагы кебек үк Реформациягә мохтаҗ һәм Петр традициясе буенча Русия Реформациядән кабат читкә китә.

Көчле хакимият тарафдарларының Петрга сокланып каравы үзе бер билге булып тора. Сталин Явыз Иванны һәм Петрны һәрьяклап пропагандалаган. Сталин заманында башка патшаларның һәйкәлләрен бәреп төшергәннәр, ә Петр һәйкәле калган. Петр турында фильмнар төшергәннәр, рәсемнәрен ясаганнар һәм болар барысы да аны уңай яктан гына күрсәткән. Сталин Петр рухына бернинди дә яңалык кертмәгән, ул башбаштаклыкны, үзәкләштерүне һәм хәрби көчкә ышанычны ахыр чиккә җиткергән. НКВД һәм ГУЛАГ — Явыз Иванның опричнина идеясенең дәвамы, ә крестьяннарны талау бәрабәренә коралланууга киткән иксез-чиксез чыгымнар — Петр алымнары.

Демократик рухлы язучылар Петрны реформатор дип түгел, милли традицияләрне җимерүче дип санаганнар. Петр эшчәнлегенә беренчеләрдән булып бәя биргән Жан Жак Руссо үзенең «Иҗтимагый шартнамә турында» дигән атаклы әсәрендә болай дип язган: «Петрда кемгәдер охшау даһилыгы гына: юктан бар ясый торган чып-чын даһилык аңар хас түгел. Ул үткәргән реформаларның кайберсе яхшы булса да, күбесе урынсыз. Үз халкының варвар халык икәнен күргән ул, әмма аның чын идарә өчен өлгереп җитмәгәнлеген күрмәгән; сугышка өйрәтәсе урынга, ул халыкны цивилизацияләштерергә теләгән. Башта ул үз халкыннан немецлар, инглизләр ясарга теләгән, әмма иң элек алардан урыслар ясарга кирәк булган. Чынлыкта исә Петр аларда юк сыйфатларның барлыгына ышандырырга тырышып, аларга булдыра алган кадәресенә ирешергә комачаулаган; бу очракта ул бала чакта мактаулы булып, үскәч бернигә яраксыз кешегә әйләнгән укучы тәрбияләүче француз укытучысы сыман эш иткән. Урыс империясе бөтен Европаны буйсындырмакчы булган һәм үзе Европа тарафыннан буйсындырылган. Татарлар, алар кул астындагы кешеләр яисә аларның күршеләре аның һәм безнең хакимнәребезгә әвереләчәк: бу революция миңа котылгысыз кебек тоела».

Петр җәмгыятендә яшәгән урыс тарихчысы Н.М.Карамзин гомеренең азагында болай дип белдергән: «Без дөнья гражданнарына әвереэлдек, әмма кайбер очракларда без инде Русия гражданнары түгел — моңа Петр гаепле!»

Петр Русиянең милли традицияләрен, әхлакый, дини һәм этник башлангычларын инкарь иткән һәм аларга каршы көч кулланган — бу җәһәттән ул чын большевик булган. Аның яңа башкаласы — Петербург бернинди тамырсыз-традициясез шәһәр идеясенең чагылышы, төрле дөньялар һәм төрле ландшафтлар чигендә калкып чыгып, ул гүя бар дөньяга тәкәббер караш ташлаган. Бу шәһәр каты җиргә түгел, ә фин сазлыклары өстенә салынган. Шул ук вакытта ул урманга да тоташмаган һәм даланың да әсәре юк анда. Пушкин әйтмешли, «из тьмы лесов, из топи болот вознесся пышно, горделиво». Анда диңгез дә чын түгел — Фин култыгы сай, диңгезгә бөтенләй охшамаган, һәм суы да төче, шуңа күрә анда агач кораблар бик тиз черегән. Венеция дә утраулар өстендә тора, әмма ул барыбер диңгездә һәм нәкъ диңгездә өстенлек итәр өчен салынган. Петербург Венециягә охшаган, ләкин ул Венеция түгел һәм беркайчан да диңгездә өстенлеккә ирешмәгән. Петербург Стокгольмга охшаган, әмма бик аз гына. Петербургта Европа шәһәрләренең күп кенә чалымнарын шәйләргә мөмкин. Анда Европаның бөтен стильләре катышкан. «Петербургта оригиналь, бары тик үзенә генә хас берни дә юк,— дип язган Федор Достоевский.— Петербург Европаның барлык шәһәрләренә дә охшаш булуы белән аерылып тора да... Анда хәтта урыс чиркәүләре дә ниндидер католиклык чалымы алган». Петербургның кыяфәтенә карап анда нинди халык яшәгәнен билгеләп булмый. Петр I нең максаты да шундый булган: бу башкалада татар традицияләре булмаска тиеш, шуңа күрә ул урыс үзенчәлекләренең барысыннан да ваз кичкән.

Башбаштаклык, көйсезлек һәм, Пушкин әйтмешли, «тәкәббер күршегә үч итеп» беркайчан да беркем дә яшәмәгән урында шәһәр салырга керешеп киреләк чагылышына әйләнгән Петербургның Петр I дән гайре бернинди тамыры да юк. Табигать, тарих һәм стихия үзе моңа каршы торган, әмма Петрның барысын да җиңеп чыгасы килгән. Пушкин бакыр җайдак турында болай дип язган:

Әй, язмышның көчле хөкемдары,
Биеклектә чая атыңның
Тоткач тимер авызлыгын тартып,
Үрә баскан кебек атың ярсып,
Тирән упкыннардан Русияне
Югарыга, өскә ашырдың.

Петр төрле мәдәниятләр һәм төрле дөньялар, Европа белән Русия, үткән заман белән бүгенге көн арасында калкып торган, анда бертөрле тотрыклылык та, ачыклык та булмаган, киресенчә, ул шуларның чигендә — гүя чиркәү болдырында басып торган, чөнки чиркәүгә дә керергә теләмәгән, шул ук вакытта православиене дә кире кага алмаган. «Чиркәү болдыры (паперть) — нуль пространство, дөньяви киңлек белән

чиркәү дөньясы арасындагы чик сызыгы». Бу тормыш бернинди нормаларга да, җәмәгатьчелек каршында әдәп-хәят кагыйдәләренә дә сыймый. Мондый урында, гадәттә, юләрләр яисә шамакайлар тора, алар тормышында да нормалар юк, алар урыны — чиркәү болдыры. Юләр белән шамакай башкалар өчен тыелган нәрсәләрне әйтә алу өчен кирәк. Тегесе дә, бусы да бу тормышка керми. Әмма юләр зат үз фәлсәфәсе булган дәрвиш суфи түгел шул, юләрдә суфидагы шикелле дини тирәнлек юк.

Петр, киенеп-ясанып тамаша күрсәтүчеләр шикелле, эпатаж яраткан һәм җәмгыятьнең гадәти нигезләрен үзгәртү белән мавыккан. Ул балта остасы булып киенеп чынлап эшләп йөргән, ясалма күлләрдә сугыш уеннары үткәргән, оргияләрдә катнашып кешелеклелеген җуя барган. Эчкечелек коллегиясе яисә «дуамал, шаярткыч һәм исерткеч собор» җыеп, Петр үзенең кәеф-сафа коруларын канцелярия рәвешенә керткән. Бөтен халык олы пост үтәгәндә, ул бөтен «соборлары» белән ишәкләргә, үгезләргә атланып яисә дуңгыз, аю, кәҗә җиккән чаналарга төялеп, туннар әйләндереп киеп тантана ясап йөргән. Аның Ливон крестьянкасыннан уйнаштан ике кызы туган. Анна Монсны хөрмәтләп искә алырлык: ул Петрны үзенә өйләндереп кенә калмаган, аннары гомер буе авыр походларда аның тугрылыклы ярдәмчесе һәм иптәше булган, соңыннан императрица Екатерина I гә әверелгән. Фантастик эпатаж.

Петрга эстетик сиземләү хас, әмма бу күбрәк геометрик: ул форма һәм симметрияне һичшиксез сиземләгән, төзелмәләрнең катлаулыларын ошаткан, әмма аңа даими эстетик тәрбия бирелмәгән, ә сәяси һәм милли традицияләр бөтенләй читләтеп үткән.

Петр — традицияләрне җимерүче типик революционер һәм шуңа күрә үз гамәлләрен көч кулланып кына башкара алган. Николай Бердяев сүзләренә караганда, «ул урыс халкының нәзберек күңелен көчләгән».

Петр бик холыксыз кеше булган — җәзалау урыннарында стрелецларның башларын үзе чабып өзгән. Аның заманында Русия крепостнойлыкка таянучы ачыктан-ачык милитаристик илгә әверелгән. Бу чорны кенәз Трубецкой «роман-герман изүе» дәвере дип атаган. «Большевиклар — ике йөз еллык роман-герман изүе җимеше. Мәскәү дәүләтчелеге татар изүе җимеше булган кебек үк... — дип яза ул. — Татар мәктәбе аттестатын роман-герман мәктәбе аттестаты белән чагыштырсаң, шундый нәтиҗәгә киләсең: татар мәктәбе алай ук начар булмаган икән әле...».

Петр Русияне үрә бастырган. Ышаныч һәм татулыкны көч алмаштырган, чиркәү һәм җәмгыять төрле өлешләргә таркалган. Крепостнойлыкны законлаштыруны нәкъ менә Петр тәгәлләгән, кешеләрне салып суктыруны һәм сатуны керткән, шуның белән ул җәмгыятьне күп елларга артка чигергән, салымнарны 6,5 мәртәбә арттырган! «1704 елдан башлап бер-бер артлы җыемнар кертелгән: камытларга, башлыкларга һәм итекләргә келәймә салудан — җир, үлчәм, авырлык, камыт, башлык һәм итек җыемнары; атлы олаулардан, олаучылардан җыемнар — яллану бәясенең уннан бер өлеше; ат һәм сыер күненнән — сажень саен, чалгы саен җыемнар, күн җыемнары; юлаучылар йортларыннан, вакытлыча файдалануга алынган йортлардан һәм почмаклардан — умарта, мунча, тегермән җыемнары; мичләрдән — кабык-кайрыдан, боз ватудан, нәүрәп-базлардан, су эчерүдән, морҗалардан җыемнар; йөзү судноларыннан — килеп туктаган, кузгалып киткән өчен җыемнар; утыннан, азык-төлек сатудан, карбыздан, кыярдан, чикләвектән җыемнар һ.б.». Дингә ышанулар өчен аерым салым салынган. Сакал-мыек үстергән өчен аерым бәяләр, туй салымнары һәм башкалар, һәм башкалар. Бу кадәр мәгънәсез, бу кадәр чамасыз, бу кадәр бөлдергеч ясак ханнарның төшенә дә кермәгән. Петр сакал-мыекка, кием-салымга каршы чыккан. Сәүдәгәрләрне урыс күлмәк-ыштаны саткан өчен чыбыркы белән суктырган, милекләрен тартып алып каторгага сөргән. Сакал-мыекка һәм кафтанга каршы көрәш аңа килешмәгән, күңелне кайтаручы коточкыч күренеш булган, ул кешеләрдә реформаларга нык каршылык тудырган. Әмма Петр моның белән генә тынычланмаган. Ул чиркәү чаңнарыннан туплар койдырган; монастырьларның вотчина керемнәрен үз карамагына алган; башта — сумалага, поташка, рәважга һәм җилемгә монополия урнаштырган, аннан соң боларга тоз, тәмәке, акбур, дегет, балык мае һәм имән табутлар өстәлгән. Дәүләт тозны кешеләр үзара килешкән бәядән ике мәртәбә арттырып саткан. Татар ханнарының берсе дә урыс халкына шушы Петр кадәр мәрхәмәтсез булмаган. Теләсә нинди хата өчен — мөлкәтне тартып алу, бөтен хокуклардан мәхрүм итү, салып суктыру, каторга, дар агачы, сәяси яки физик үлем кулланылган. Корабльләр төзүдә яки галераларда үләргә тиешле тоткыннарны алдан ук билгеләп бирүне дә нәкъ менә Петр керткән. Ул «берничә мең каракны» әзерләргә һәм аларны берәр кальга төзелешенә җибәрергә кушкан. Петр заманында заводлар белән берләштерелгән махсус төрмәләр — концлагерь башлангычлары барлыкка килгән. Петр үз халкының иреге хакында түгел, үз казнасы турында гына уйлаган, аңа гражданнар түгел, авыр эшкә яраклы кешеләр кирәк булган. Русиянең иксез-чиксез байлыклары җирлегендә гамәлләрен акыл белән, икътисадны һәм сәясәтне аңлап кылса, Петр шул ук акчаларны халыкны бөлдермичә дә табар иде. Аның дәверендә халык саны биштән бер өлешкә кимегән!

Бу хәлләргә җавап итеп халык күпләп-күпләп, кайвакыт бөтен бер авыллары белән Польшага, Донга, башкортларга, Урал аръягына, Себер шәһәрләренә качкан. Аннары бөтен ил буйлап качак солдатлар җитәкчелегендәге юлбасарлар төркемнәре пәйда булган, алар яхшы коралланган атлы отрядларга берләшкән-

нәр дә зур авылларны тар-мар иткәннәр, казна җыемнарын туктатканнар, шәһәрләргә бәреп кергәннәр. «Түбәндәгеләр талау-сугышулары белән югарыдагыларның башбаштаклыгына җавап биргәннәр: бу исә өстәге законсызлык һәм гамәлгә яраксызлык белән түбәндәге чиксез-исәпсез өметсезлекнең бер-берсен яшерүе шикелле булган. Башкаладан килгән приказный кеше, узып баручы генерал, тын почмакта яшәп ятучы дворян шушы явыз үзгәртеп коручының указларын тәрәзәдән ыргытканнар һәм алар, урман юлбасары белән бергә, башкалаларда ярымдержавачыл Сенат һәм шведча нигезгә корылган тугыз, ә соңрак ун коллегиянең даими рәвештә чикләнгән ведомстволары эшләп торуы хакында бик борчылмаганнар. Закон чыгару эшенең тышкы бизәге гомуми ямьсезлекне каплап торган». Петр заманында дүрт коточкыч фетнә һәм берничә заговор оештырылган, аларда хәтта Петрның газиз улы да катнашкан. Алар барысы да яңалыкларга каршы булганнар.

Халык арасында ике легенда йөргән: берсе — самозванец Петр, икенчесе антихрист Петр турында. Петрның кыяфәте чиктән тыш ят булган. Ул патша таҗы һәм мантия кимичә гади матрос кебек киенгән, кулында — патша таягы урынына трубка, гвардия офицеры кебек сүгенгән һәм сугышкан, аракыны солдат шикелле чөмергән. Халыкта бер фикер кабынып-кабынып алган: чын патша микән соң ул? «Ул, имеш, немец хатыныннан туган уйнаш бала, аны алмаштырганнар, китереп ташлаганнар икән. Шуңа күрә дә немец киемнәре кияргә куша, бөтен илгә чит җир кешеләре тула, алар, черкиләр шикелле, урыс халкының канын эчәләр дә чит җирләргә китәләр». Петр монахлыкка «салым түләүдән качып һәм ялкаулыктан, бушлай ипи ашарга» китәләр дип уйлап, чиркәүне кысрыклый башлагач, халык арасында Петр антихрист икән дигән имеш-мимешләр туган. Аның реформаларын халык аңламаган һәм кабул итмәгән, алар халыкны өркеткән генә. Үз максатларына ирешер өчен Петр үзен дә, акча да, кеше гомерләрен дә кызганмый. Петр яңа башкаланы үзенең җәннәте — «парадиз»дип атаган, әмма ул халык каберлегенә әйләнгән.

Петербург Көнбатышка табыну идеологиясенең үзенчәлекле нәтиҗәсе булып кына калмаган, ул бары тик башкала вазифалары бәрабәренә генә яши алган. Гоголь әйтмешли, «Мәскәү Русия өчен кирәк, ә Петербург өчен Русия кирәк». Петербург Русиядән башка яши алмаган, беренче чиратта, ул — Русия императорлары резиденциясе. Ул үзе, асылда, Русия булмаган, нәкъ менә бүгенге Мәскәү шикелле — Мәскәүгә килеп кергәч, Русиядән чыгып киткән кебек буласың. Аның калыбы гына Русиянеке, ә рухы һәм яшәү рәвеше буенча — аерым бер дәүләт.

Петербург Русия җәмгыятенең бөтен күзәнәкләренә үтеп кергән казенщина барлыкка китергән. Петербург яшәешенең бөтен мәгънәсе — Русия белән урыс җаны теләгәнчә түгел, швед-немец үрнәгендә идарә итү. Шинель нәкъ менә Петербургка бәйле төстә күз алдына килә. Шинель кешедән дә өстен һәм кыйммәт, ул Петр империясенең рухын чагылдыра. Акакий Акакьевич бернинди дә башка шәһәрдә түгел, бары тик Петербургта гына туа алган. Петербург — шинельнең кеше рухы өстендә тантана итүче казенщина гәүдәләнеше ул. Бу шәһәрдә үзенчәлекле бер Петербург характеры ясалган. Антон Чехов «Билгесез кеше хикәясе»ндә болай дип язган: «Орловның тышкы кыяфәте Петербургча иде: тар җилкә, озын бил, эчкә баткан яңаклар, күзләре сүрән һәм билгесез төстә, башында тонык төскә буялган чәч, сакал-мыек. Йөзе пөхтә, таушалган һәм күңелгә ятышсыз».

Петр Русия дәүләтчелеге нигезенә зур каршылык салып калдырган. Аңа кадәр Көнбатыш яклы идеяләр фәлсәфи булса, Петрдан башлап алар шведлардан бигрәк Мәскәүгә каршы торучы төньяк башкала рәвешен алган. Бу әверелешне халык хәрәкәте әзерләмәгән, бу әверелеш халыкчанлыкны кире каккан һәм җәмгыятькә ят элитар төсмер керткән. Халыкчанлык башка нәрсәләрдә: бунтларда, стихияле басып алуда, казаклар качаклыгында, революцияләрдә чагылган. Тарих тарафыннан әзерләнмәгән ясалма әверелеш каршылыгы дәүләт белән халык арасында упкын тудырган. 1861 елда Юрий Самарин бу хакта болай дип язган: «Бу — халыкның барлык рәсми, законлы нәрсәләргә, ягъни Урыс җиренең халык булмаган яртысына тулысынча ышанмавы... Манифест, мундир, түрә, указ, губернатор, төреле руханилар, югары әмерләр — бар да ялган. Боларның барысына да халык зәмһәрир суыкларга, җил-бураннарга, корылыкка түзгән кебек үк түзә, әмма бернәрсәгә дә ышанмый, берни дә танымый, бернәрсә хакына да үз инануларыннан ваз кичми. Дөрес, халык аңында аның үз патшасы яши, әмма ул Петербургта утырып губернаторларны билгеләп куючы, югары әмерләр чыгаручы, гаскәрләрне хәрәкәткә китерүче патша түгел, ниндидер башка — үзләре уйлап тапкан ярым әкияти патша, ул иртәгә үк исерек дьячок яисә чиксез вакытка иреккә җибәрелгән кеше сурәтендә кинәт кенә пәйда булырга мөмкин».

Петр законга түгел, башбаштаклыкка таянучы үзенчәлекле сәяси культураны үстереп җибәрүдә башкалардан уздырган. В.О.Ключевский сүзләренә караганда, «ул үз канын Мәскәү сәясәтенә бердәнбер нык юнәлеш бирүче инстинкттан — башбаштаклыктан чистарта алмаган».

Бүтән яктан караганда, азатлык идеясе хакимиятнең башбаштаклыкка хокукы кадәр үк каршылыклы булып чыккан, ул йә тормыштан география киңлекләренә качуда, дәрвишлеккә китүдә, йә народоволецларның үз хокукларын бунт һәм террор ярдәмендә раславында чагылган. Ниһаять, революция елларында жи-

нең чыккач, азатлык кабат башбаштаклык урнаштырган. Азатлык башбаштаклыкка хокук алу гына булып чыккан, ул үз-үзен раслауның уңай юнәлешен тапмаган. Хокук мантыйгы урыс акылына дошман булып чыккан. Урыс кешесе намус кушканча яшәүне закон буенча яшәүдән өстен күргән һәм шул ук вакытта үзен барыннан да ныграк газаплаучы башбаштаклыкны каргаган. Ул башбаштаклыкка каршы фетнә күтәргән, ә фетнә үзе үк ачыктан-ачык һәм кыргый башбаштаклык бит инде ул.

Язмыш ирониясе буенча Русия тарихындагы күренекле шәхесләр дә гаять каршылыклы. Петрдан алдагы патша — Явыз Иван да нәкъ шулай холыксыз булган, үзе дәүләт кора башлаган да аннары үзе төзегәнне үз куллары белән җимереп барган. «Явыз патша күп уйлады, әмма уйлаганын аз башкарды, аның үз замандашлары аңына һәм нервларына йогынтысы дәүләт тәртибенә ясаган тәэсиренә караганда көчлерәк. Мәскәү дәүләтенең тормышы Иваннан башка да моңа кадәр һәм моннан соң корылган кебек корылыр иде, әмма аннан башка бу корылыш җиңелрәк тә, шомарак та эшләнер иде: мөһим сәяси мәсьәләләр ул әзерләгән тетрәнүләрдән башка хәл ителер иде. Аның патшалык итүенең тискәре әһәмияте мөһимрәк». В.О.Ключевскийның бу юллары Петр I турында язылган шикелле. Явыз Иваннан соң фетнә башланган һәм Петрдан соң да Русия озакка сузылган кризис кичергән — түнтәрелешләрнең, крестьян һәм мөселман восстаниеләренең болганчык дулкыны күтәрелгән, Пугачев «янгыны» заманында ил бөтенләй идарә ителә алмаслык хәлгә килгән.

Меньшиков Русияне «төзелеп бетмәгән олы храм» дип атаган, әмма алга таба Русия инде Петр планы буенча төзелмәгән, хәер, булган микән соң ул нинди дер башка план? Петрдан соң сәнәгать сизелерлек уңышларга ирешмәгән, тышкы сәүдә дә чит ил кешеләре кулында кала биргән, эчке сәүдә какшаган, шәһәрләр үсмәгән, ә крестьяннар өметсезлеккә бирелгәннәр.

Илаһым, Синең белән мин
Сүз көрәштермәк идем,
Сират күпере өстендә
Шаярып йөрмәк идем.
Тиле булганмын икән бит —
Ярлыка берүк, Ходам!
Шәфкать иңдер ерактагы
Дөньялар арасыннан...
Диден: «Яшәү бирәм җиргә
Һәм җәзам булыр — үлем,
Яшәвең дә, үлемең дә
Ихтыярымда минем».
...Ярый, гөнаһлы тормышны
Бик күп данладык... Җитәр!
Шәрекъ якны мин күтәрәм,
Гареп якны син күтәр.

*А.С. Пушкин*
*«Подражание Корану»*
*Зөлфәт тәрҗемәсе*

Петр башлаган көнбатышчылыкның хәрби эштә (анда уңышлар менә дигән), фәндә, техникада гына түгел, рухи тормышта да шактый уңай нәтиҗәләре булган. Ахыр чиктә Пушкин — барлык язучылар арасында иң милли язучы — Европа әдәбияты, иң элек француз әдәбияты үрнәкләрендә тәрбияләнгән. Пушкин Чаадаевка французча болай дип язган: «Дустым, мин Сезнең белән Европа телендә сөйләшәчәкмен. Ул миңа үз телебезгә караганда якынрак». Бу — ул чордагы гомуми караш. Француз теле һәм мәдәнияте, Русиянеке булган бөтен нәрсәдән аермалы буларак, цивилизация итеп кабул ителгән, әмма шул ук вакытта миллилекне үстерү омтылышы да көчәйгән. Пушкинга кадәрге бер шагыйрь әйтмешли, «рукой победной, но в рабстве мы умами, клянем французов мы французскими словами».

Пушкин француз әдәбиятын ничек кенә яратса да, урыс тарихы турында язган, халык шигъриятен һәм җырларын җыйган, әкиятләрен эшкәрткән. Державин — күчеш чоры шәхесе, халыкчанлыктан бигрәк империячел башлангычны чагылдырган шагыйрь булса, Пушкин — урыс шагыйре, ул ачыктан-ачык һәм абсолют милли, ул — чын урыс әдәбиятының лаеклы символы. Пушкиннан башлап Европа һәм урыс әдәбияты бер-берсенә якынлашкан. Тургенев беренчеләрдән булып Европа әдәби даирәсенә җитди йогынты ясаган, аннары Достоевский һәм Толстой Көнбатышны үзләренә буйсындырганнар. Русиянең Петрдан соңгы рухи тормышы Европа йогынтысына бирелгән. «Урыс әдәбияты — Лермонтов һәм Гогольдән алып бүгенге көнгә кадәр — Европа романтизмы ясаган борылыш нәтиҗәсе, урыс әдәбияты анда катнашкан, аны дәвам иткән һәм аның бер бөртегеннән дә ваз кичмәгән,— дип яза Владимир Вейдле.— Урыс музыкасы халык музыкасына караганда Көнбатыш музыкасыннан күбрәк алган һәм ул Бетховеннан соңгы Көнбатыш музыкасына күбрәк бәйләнгән. Хәтта Иванов һәм Врубель иҗатында үзенең дини нигезенә тугры калган

урыс рәсем сәнгате дә, Европа сәнгатен әйләнеп узып, икона язуга кире кайта алмаган. Ул бары тик Европа сәнгатендә тамыр җәйгәч кенә, кайчак нәкъ Европача, әмма шул ук вакытта Көнбатыштан бәйсез яңа формаларга ирешкән. Урыс философиясе — Шеллингтан һәм Гегельдән, урыс фәне Көнбатыш фәненнән башлана. Хәтта урыс дин гыйлеменең тамырлары да үзенең көнчыгыш-христиан традицияләренә никадәр тоташса, Көнбатышның фәлсәфи һәм дини фикерләре традициясенә дә шулкадәр үк бәйләнгән. Биредә хикмәт безнең бөтен чит нәрсәне сеңдерә баруыбызда да, Көнбатыш басымында да түгел, унтугызынчы гасыр Көнбатышта да, Русиядә дә бер үк».

Әмма әдәбиятның, язучыларның үзләре кебек үк, халык тормышыннан читләшүе күзгә ташлана. Тургенев күбрәк Франциядә яшәгән, Гоголь Римда вафат булган, башкалар Русиягә кайтып-китеп йөргәннәр. Толстой халык белән бергә яшәргә тырышып караган, әмма ул граф булган һәм, ниһаять, үз йортыннан бөтенләй китәргә батырчылык иткәч, ниндидер билгесез Русия эзләп барганда юлда вафат булган. Бүген Тютчевның атаклы юлларын кабатларга яраталар: «Умом Россию не понять, аршином общим не измерить, у ней особенная стать, в Россию можно только верить». Әмма шагыйрь үзе Русияне ничек кенә яратса да, анда яшәмәгән, чып-чын Русияне ул өнәмәгән. Тютчев Германиядә яшәгән, ул чын Русияне түгел, күңелендәге күзгә күренмәс Русияне яраткан. Ул нәрсә яраткан да нәрсәгә ышанган соң? Дөнья йөзендә булмаган Русиягәме?..

Европа эшләренә йогынты ясарлык бөек Русия Петрдан башка булмас иде, әмма Петр большевизмны әзерләгән, ә бу ахыр чиктә илне һәлакәткә китергән. Владимир Вейдле болай дип язган: «Ахыр чиктә без Петрга Петербург Русиясе тудырган бөтен бөек гамәлләр өчен дә һәм шул Русияне җимергән һәлакәт өчен дә бурычлы».

Петр илгә Европа культурасын кертә алмаган, чөнки ул, Европа илләрен алдынгылар рәтенә чыгарган факторларга игътибар итмичә, Европа культурасының ахыргы нәтиҗәләрен генә алган. Европада капитализм барлыкка килүне, гадәттә, Макс Веберның җиңел кулыннан, протестантлык белән бәйлиләр. Бу да үзенчә дөрес, билгеле. Әмма, нигездә, православие һәм исламның иҗтиһад көче католиклык һәм протестантлык көченнән һич тә ким түгел, тик ниндидер бер мизгелдә православие урыслар үсешен тоткарлый башлаган һәм бу аның дәүләт белән тыгыз бәйләнгәнлегеннән килгән.

Европада католиклык дәүләт йогынтысыннан читтә торган, папачылык дәүләттән өстен институт булган, шуңа күрә христианча фикер шактый мөстәкыйль үскән. Ә протестантлык исә чиркәү иерархиясенә бөтенләй дә каршы чыккан. Ул дәүләт басымыннан да, чиркәү басымыннан да азат булган. Православие исә Алтын Урда кысаларында гына тулы азатлыкка ия булган, шул чорда ул төрле монастырьларда үсеш алган, әмма соңыннан чиркәү дәүләткә хезмәт күрсәтә башлаган һәм дини фикер «кануннар» эчендә катып калган.

Исламда да шул ук хәл килеп туган. Ислам, хәлифәтләр басымы астына эләккәнче, ирекле үскән. Ул урта гасырларда Көнчыгышта гына түгел, Көнбатышта да кешеләр аңында хакимлек иткән. Бөтен Европа математиканы, медицинаны, философияне мөселман галимнәреннән өйрәнгән. Ислам өчен урта гасыр караңгылык заманы түгел, киресенчә, менә дигән үсеш дәвере булган, әмма аннары ирекле фикер һәлакәткә дучар ителгән. Шуның белән бергә барлык мөселман дөньясы Европадан коточкыч рәвештә артка кала башлаган. Мәзһәбләрдә оеп калып, ислам дөньяны үзгәртүче дин һәм фәннәр тупланмасы буларак үз әһәмиятен югалта башлаган. Шунысы кызыклы: Екатерина II нең диннәргә тигез караш турында указы чыгып, ислам үз язмышын үзе хәл итәргә тиеш булгач, ә дәүләт дини бәхәсләрнең асылы белән кызыксынмый башлагач, татарлар, ислам Реформациясен башлап, тарихи сикереш ясый алганнар. Алар мәдрәсәләрне яңа идеяләр бакчасына әйләндергәннәр, һәм бу хәл XIX — XX гасырда халкыбызның алга таба үсешенә хәлиткеч этәргеч ясаган.

Дини рух ирегеннән тыш Европа үсешенең тагын бер факторы — үзидарәчел шәһәр-дәүләтләр барлыкка килү. Русиядә ике ирекле шәһәр: берсе — Новгород, икенчесе Псков булган. Явыз Иван аларны җимергән. Нәтиҗәдә бөтен ил башкалага гына хезмәт күрсәткән, бүтән шәһәрләр исә башкала өстәленнән коелган валчыклар белән канәгатьләнергә мәҗбүр булганнар.

Европада ирекле Ганза шәһәрләре белән беррәттән, университетлар да әһәмиятле роль уйнаган, алар фән һәм дөньяви фикер үсешенең үзидарәчел үзәкләренә әверелгәннәр. Урта гасырлар дөньясында Кордова ислам университеты да нәкъ шундый вазифа үтәгән, Европа фәне йолдызлары нәкъ шуннан чыккан. Петр фәннәрнең әһәмиятен бик аңлаган һәм шуңа күрә дә Русия Фәннәр академиясен ачкан. Әмма ул, Европаның заманча технологияләрен кертсә дә, Европада җәмгыятьне алга җибәргән сәяси ирекләргә бөтенләй юл бирмәгән. Шулай да, самодержавие басымына карамастан, нәкъ менә Русия университетлары мәгърифәт һәм ирекле фикер, хәтта революцион чыгыш учакларына әверелгәннәр. Аларны вакыт-вакыт хөкүмәт күзәтчелегенә куймакчы булганнар. Күпләргә мәгълүм Магницкий Казан университетын «ирекле фикер һәм ялган акыл рухы» өчен бөтен халык алдында җимереп, ябып куярга тәкъдим иткән. Моңа җавап

итеп Александр университеттагы хәлләрне төзәтергә кушкан. Шуннан соң Магницкий университетны билгеле бер вакытка казармага әйләндергән инструкцияләр әзерләп биргән.

Петр чыннан да «көнбатыш тарафдары» булса, вакыт-вакыт җыелып алучы соборларны даими парламентка әверелдерер иде, ә аның соборларга исе китмәгән һәм Мәскәү соборларының дәвамчысы булып түнтәрелешләр оештыручы гвардия казармасы торган. Ул Петербургны башка шәһәрләр исәбенә төземәскә, ә аларга ирекле үсеш мөмкинлеге тудырырга, крепостнойлык кертү урынына җир язмышын крестьяннарның үзләренә тапшырырга тиеш булган. Чөнки Русиянең территориясе гаять зур һәм игътибарны аны нәкъ менә тиешенчә коруга юнәлтергә кирәк булган. Ул балаларны мәктәпләрдә көчләп укыткан, ә балалар исә мәктәпләрдән солдатлар рекрутлыктан качкан кебек качканнар. Петр Европаның күренекле нәтиҗәләренә игътибар иткән, әмма бу нәтиҗәләргә ирешү юллары белән кызыксынмаган. Мәсәлән, чит илләрнең хәрби казанышларын Петр бары тик территорияләр яулап алу өчен генә файдаланган. Аның диңгезгә чыгу омтылышы аңлашыла, әмма яңа җирләрне китереп кушуның аларны тиешенчә корган тәкъдирдә генә мәгънәсе бар, ирекле шәһәрләрдән һәм ирекле крестьяннардан башка бу эш — нәтиҗәсез. Арнольд Тойнби фикеренчә: «Үсеш билгеләре ачык күренгән җәмгыять яңа җирләр яулап алуга омтылган очракта, аның бу гамәл аркасында үзенең эчке көчләрен какшатачагын алдан ук әйтеп бирергә мөмкин». Территория экспансиясе илнең үзәген какшату исәбенә башкарылган, чөнки бу җирләрдән халык ирекле тормыш эзләп качкан. Петр башлаган яңарту процесслары ярым-йорты булган һәм үзендә империячел башлангычны «катырып куйган» җәмгыять корылышына кагылмаган. Лев Троцкий Петр турында болай дигән: «Европа коралы һәм Европа заемнары — югарырак культура җимешләре — үсешне тоткарлый башлаган царизмны көчәйтүгә китергән. Бер үк вакытта традицион культура катламнары каршылык күрсәтә башлаганнар, алар Петр реформаларына каршы бунтарь фикерләр үстереп җавап биргәннәр.

Русиядә бунтарьлык, революцион башлангычлар Европадагы кебек законнар чыгару белән тигезләнмәгән. «Урыс революциясендә без цивилизация нормаларын кире кагучы һәм хаосны ирекка чыгаручы Көнчыгыш башлангычының хакимлеген күрәбез» дип әйткән Николай Бердяев хаклы түгел. Революцион фикер Көнчыгыштан түгел, Европадан кергән һәм Петр белән Екатерина ашлаган туфракта бик тиз тамыр җибәргән. Ул фикердән тирәнлек тә, халыкның тарихын һәм рухын аңлау да таләп ителмәгән, ул үткән заманны бүгенгенең һәм киләчәкнең нигезе буларак бөтенләй кире каккан. Революция үзҗитешле бунт буларак кабул ителгән. Плеханов фикере буенча, «революциянең казанышы — иң югары закон». Бу тезисны урыс фикере күтәреп алган һәм үстергән. Достоевский «Бесы» әсәрендә язган кебек, чикләнмәгән ирек идеясе чикләнмәгән деспотчылыкка китергән.

Яңадан үсеп чыккан интеллигенция хакимиятне чынлап тәнкыйтьләгән һәм шуның белән революцияне әзерләгән дә. Ул — җәмгыятьнең иң гыйлемле өлеше, чын урыс культурасы вәкиле, әмма хакимияткә үтеп керә алмаган. Шуңа күрә интеллегенция объектив рәвештә дә, субъектив рәвештә дә хакимияткә каршы торган. Ә инде белемле дә, идарә итүче катлам да булган дворянчылык мәдәният ясау монополиясен җуйган һәм әкренләп үз урынын интеллигенциягә биргән. Декабристлар чыгышыннан соң дворяннар да хакимияткә керү мөмкинлегеннән мәхрүм калганнар. 1825 елның 14 декабре гвардиянең сарай түнтәрелешләре турындагы соңгы искәртмәсе булган, моннан соң урыс дворянлыгының сәяси роле тәгәлләнгән. Алга таба сәхнәдә бу сүзнең саф урысча мәгънәсендә — «саф интеллигенция», ягъни хакимияткә каршы бары тик нык тәнкыйди караштагы интеллигенция барлыкка килгән. Русиянең иң гыйлемле кешеләре арасында революционерларның күплеге очраклы хәл түгел: Пушкинның, Радищевның, Герценның дусларыннан башлап бөтендөнья анархизмы терәкләре — Бакунин белән Кропоткинга кадәр. Чернышевский белән Добролюбов бер баскыч түбәнрәк торсалар да, һичсүзсез, югары культура вәкилләре.

Ләкин алга таба культурасы әзрәк, әмма революция хисе күбрәк булган, революция рухын күбесенчә Европада өйрәнгән язучылар һәм җәмәгать эшлеклеләре барлыкка килгән. Аннары инде ярым интеллигентлар пәйда булган, алар урыс һәм Европа философиясенең сәяси ягын гына кабул иткәннәр, «бер уч сәяси идеянең диннән дә, культурадан да, тормышның һәм тарихның калган барлык якларыннан да мөһимрәк» икәненә ышанганнар. Сул эсерлар, меньшевиклар, большевиклар — барысы да күбесенчә публицистлар — революцион публицистлар, ә кайвакыт аларның иң күренекле вәкилләре булганнар. Борис Савинковның «Конь бледный» әсәре болар арасында чыгарма түгел, ә шул катламнарның карашын чагылдырган әдәбиятның символик үрнәге.

Мәскәүне Алтын Урда заманында югары күтәргән православие үзенең иҗтимагый позицияләрен әкренләп җуя барган. Таркалган Алтын Урданы бөек урыс державасына җыйган православие ул заманда рухландыргыч идея булган. Достоевскийның урыс халкын «Ходайны йөртүче халык» дип атавы очраклы түгел. Русиядә урыс рухына аеруча хас һәм иҗтимагый фикер үсешендә бик күп нәрсәләрне билгеләгән дини эзләнүләр рәсми православиедән читтә, вакыт-вакыт хәтта чиркәү традицияләренә каршы да алып барылган. Православие чиркәве дәүләт белән чамадан тыш нык элемтәдә торган, бу «симфония» еш кына держава

мәнфәгатьләренә хезмәт күрсәтүгә, дәүләтнең гаделсез корылышын яклауга кайтып калган. Лев Толстой болай дип язган: «Безнең иерархия үзе дә тота һәм халыкка да сеңдерә торган дин — алдау гына да түгел, әхлаксыз ялган да ул». Ниндидер бер мизгелдә православие урыс җирләрен җыючыдан үсешне тоткарлаучыга әйләнгән. Көнбатыш яклы карашлар күбесенчә дини эзлеклелек белән ризалашмауны чагылдырган. Рухи кризис турында бик күпләр язган, әмма шулар арасында иң әһәмиятле факт — Лев Толстойны чиркәүдән аеру. Бөтен ил гөнаһка чумган, хлыстовчылыкка кадәр барып җиткән, тик нигәдер чиркәүдән бары тик Толстойны гына аерганнар. Урыс этникасының нигезе булган православие чиркәве, урыс культурасы үсешенең Лев Толстой сурәтендәге иң югары ноктасында, урыс рухының нигези үзгәрешләрен чагылдыручы бөек фикер иясен кире каккан. Мондый әверелеш Мәскәүнең урыс җирләрен җыючы буларак төп тәшкилияте — рухияте бетүгә баруын аңлаткан. Петр салып калдырган миналар нигезнең үзен шартлата башлаган, гәрчә әлегә православиенең сәер образлары йә Лев Толстойның мужик Христосы кыяфәтендә, йә Александр Блокның кызыл армияче Христосы кыяфәтендә каядыр күренгәләп торсалар да:

Мы на горе всем буржуям
Мировой пожар раздуем,
Мировой пожар в крови —
Господи, благослови!
…Так идут державным шагом,
Позади — голодный пес,
Впереди — с кровавым флагом,
И за вьюгой невидим,
И от пули невредим,
Нежной поступью надвьюжной,
Снежной россыпью жемчужной.
В белом венчике из роз —
Впереди — Иисус Христос.

Н.Н.Зворыкин болай дип язган: «Большевикларның мескен бер төркеме бик тиз һәм һич көтмәгәндә куәтле Русия империясен яулап алгач, хәйран калган чит ил кешеләре: «Дөньяда иң көчле урыс гаскәре ничек итеп үзенең патшасына хыянәт итә алган? Әле кайчан гына үз «патша атакаен» өзелеп яраткан күпмиллионлы урыс халкы ничек итеп аны — мәсхәрәгә, ә үзенең бөек ватанын хурлыкка һәм бөлгенлеккә дучар иткән?» — дигән сораулар яудырганнар. Бу сорауларга җавап эзләп, автор мондый фикергә килгән: революция — 1861 елда крепостнойлыктан азат итүгә юнәлдерелгән уңышсыз реформаның аяныч нәтиҗәсе, әлеге реформага «тантаналы стиль һәм оста канцелярия риторикасы белән бизәлгән ниндидер кыюсызлык, кабалану, әйтеп һәм төгәлләп бетермәү хас. Ул киләчәктә барлык урыс халкына мул тормыш тәэмин итәрлек, төптән уйланылган, кискен социаль-икътисади борылыш ясарга карар иткән бөек реформаторның даһи иҗатының ачык билгеләнгән, куәтле, киң колачы дигән тәэсир тудырмый: ул крепостное правоны гамәлдән чыгаруның өлгереп җиткән зарурлыгына җавап булып кына чыккан». Русиядә барлык реформалар шушы стильдә узган һәм барлык бәлаләр шул кыюсызлыктан килә.

Крепостное право Русиянең икътисади үсешен нык тоткарлап торган, чөнки Русиянең төп халкын крестьяннар тәшкил иткән, ә алпавытлар һәм дворяннар турыдан-туры аларга бәйләнгән. Сәүдәгәрләр белән һөнәрчеләр кечкенә катлам тәшкил иткән һәм дәүләт эшләренә берничек тә йогынты ясый алмаган. Өстәвенә Русиядәге крепостнойлык дөньяда иң начары булган. Крестьян Европадагы сыман җиргә дә, хәтта мөлкәткә дә түгел, ә җирбиләүчегә беркетелгән, бу хәл абсолют башбаштаклык тудырган. Крепостнойлык шәһәр белән авыл культуралары арасында эчке конфликт барлыкка китергән. Петр заманында бу конфликт билгеләнеп кенә калган булса, тора-бара принципиаль каршылыкка әверелгән. Социалистик революцияне, нигездә, шушы конфликт әзерләгән.

Иң беренче ялгыш авыл общинасы ролен урыс җәмгыятенә хас эчке күренеш буларак дөрес бәяләмәүдән гыйбарәт. Заман дәүләтнең патриархаль общинадан котылуын таләп иткән, әмма моның урынына әлеге общинаның крестьян өстеннән хакимлеге генә беркетелгән. Алпавыт һәм дворянны община алмаштырган. Авыл общинасы барлык халыкларда да булган, әмма үсешләренең билгеле бер шактый түбән дәрәҗәсендә генә. Җир эшкәртүдә алга китеш нәтиҗәсендә община хутор хуҗалыкларына таркала башлаган. «Урыс крестьяннарын крепостной бәйлелектән азат итү максатында — алар үрчи барган саен, артык халык чыгып китә барсын дигән нияттә, авыл общинасыннан чыгу өчен уңайлы шартлар тудырырга кирәк булган; әмма моның урынына крестьяннарны, тимер кыршау эченә тыккандай, авыл общинасына бикләп куйганнар, үзләренә дә, күпсанлы бала-чагаларына да общинадан чыгарга ярамаган; бу исә бик зур социаль-икътисади хата булган, нәтиҗәдә үзенең томаналыгы аркасында һаман искечә иген игеп кенә тамак туйдыра белгән авыл халкы шул тып-тыгыз авыл мәйданында тыгылып яткан». Авыл общинасының ни иреклe, ни уңдырышлы җирләре дә булмаган, шуңа да карамастан ул крестьяннарны иреккә дә җибәрмәгән. Бу

шул ук крепостнойлык булган, әмма бүтән рәвештә генә. Крепостнойлык рухының җәмгыятьтә никадәр нык тамыр җәйгәнен аннан соңгы тарих та ачык күрсәтеп бирде: колхозлар ил өчен җимергеч бу тәҗрибәне җентекләп кабатладылар.

Крестьян мәсьәләсен төрле юллар белән хәл итәргә мөмкин иде. Иң гади юлларның берсе — яңа җирләр басып алу, Русиядә мондый җирләр хәтта кирәгеннән артык булган. Борынгы греклардан алып америкалыларга кадәр күп кенә халыклар шушы юлны сайлаганнар. Җирләре чикле булган Европа авыл хуҗалыгын камилләштерү алымын кулланган, ә артык халыкны шәһәрләр йотып барган. Ахыр чиктә халык үзе күчеп киткән. Мәсәлән, Швейцария кешеләре шул рәвешле бик күп илләргә, шул исәптән Русиягә дә килеп чыкканнар. Русиядә алар швейцарлар булып эшләгәннәр. Русиядә исә мөмкин булган шушы юлларның барысын да кире какканнар. Русиянең мәсьәләләрне хәл итүдәге гадәти оригинальлеге дөньяның бер җирендә дә булмаган юл уйлап табудан гыйбарәт. Моның аркасында крестьяннар һәм алар белән бергә бөтен ил революция тегермәненә куып кертелгән. Крестьяннар җир азлыгыннан зарланганнар, шул ук вакытта иксез-чиксез җирләр буш яткан, шәһәрләр үсмәгән һәм шуңа күрә алар теләгән кешеләрнең барысын да кабул итә алмаганнар. Крестьяннардан гайре барлык сыйныфларга да гражданлык хокуклары бирелгән, ә крестьяннар исә һаман да тарихи-иҗтимагый искелек калдыгы булган авыл общинасы тоткынлыгында ятканнар. Крестьяннарны Себергә күчереп утырту да халыкны тиешенчә урнаштыру мәсьәләсен хәл итә алмаган, өстәвенә яңа урыннарда да җир эшкәртү һаман шул ук бозык нигезгә корылган. Столыпинның общиначы крестьяннарны отрубларга (община җиреннән кисеп алып крестьян милкенә бирелгән җир кисәкләренә) күчерү турындагы законы тарихи яктан дөрес булса да, реформа буларак шактый соңарган.

Урыс-япон, аннары Беренче бөтендөнья сугышы ил үсешендә техника яңалыкларына таянса да, сәяси ирекләрне кире каккан Петр I моделенең уңышсызлыгын күрсәткән. Русия, крестьяннар мәсьәләсен хәл итми торып, индустриальләштерүгә күчә алмаган, билгеле. Ул чын индустриальләштерүне сәяси ирекләрдән, иҗади рухтан башка үткәрә алмаган. Революция нәкъ менә шул коллизия тарафыннан һәм, ниһаять, крестьяннарга җир бирерләр дигән өмет белән әзерләнгән.

Мәскәүнең нигезенә салынган Чыңгыз хан рухы, күп кенә әверелешләрдән соң, үткәннәргә бәйләнешсез төстә, элеккеге культураны җимерү, уйдырма тарих хакына миллилектән баш тарту буларак, мәгънәсез һәм кешелексез революция янгыны рәвешендә дөнья йөзенә ыргылып чыккан. Революция чын культура үстереп чыгарырга сәләтле бөтен орлыкларны җәмгыятьтән чыгарып ташлап халыкның генетикасына зыян салган. Ярым зыялы кеше Петрның реформаторлык рухын мәгънәсезлеккә әйләндергән совет машинасының нигезенә әверелгән. Аннары теләсә кайсы культура вәкилен җир йөзеннән юк итү башланган.

Социализм ялган индустриальләштерүнең иң кыргый юлын — крестьяннарны эксплуатацияләү бәрабәренә үсешне сайлап алган һәм иң булдыклы крестьяннарны (кулакларны) кырып бетереп, игенчеләрнең калганнарын җирдән биздереп, иске бәлаләргә яңаларын өстәгән. Петр заманындагы вакыйгалар кабатланды: сәнәгатьне үстерү крестьяннар җилкәсенә төште, яңа социаль технологияләр тәкъдим ителмәде, ә фәнни фикер хәрби өлкәдә генә үсеш алды.

Социализм башта, Петр реформалары кебек үк, икътисадта, тышкы сәясәттә, фәндә сизелерлек нәтиҗәләргә китергән, әмма тора-бара иҗтимагый фикер катып калган, ул коммунистик мәзһәбкә — катгый кануннар җыелмасына әверелгән, алардан читкә китү мөртәтлеккә тиң иде. Сәяси структуралар чамасыз үзәкләштерелде, бөтен идарә, барлык финанслар, барлык идеяләр Мәскәүдә генә яши ала иде. Мәскәү исә, нәкъ Петр заманындагы Петербург сыман, көннән-көн төзекләнә барды, чәчәк атты, ә төбәкләрдә төзелеш тыелды, бөтен мал-мөлкәт башкалада тупланды. Социалистик әверелеш илнең интеллектуаль һәм икътисади яктан йончуына китерде.

Урыс рухын тергезүгә каршы беренче киртә — эмиграция, җәмгыятьнең иң интеллектуаль, иң эшлекле, иң тәҗрибәле өлеше чит илләргә качкан. Аннары — Гражданнар сугышы, 30 нчы елларда интеллигенцияне һәм руханиларны физик яктан юк итү. Урыс дворяннарын илдән куу һәм кырып бетерү мәдәни традицияләрне какшаткан. Сугыш бу процессны җиренә җиткергән: көчле ихтыярлылар фронтка киткән һәм күбесе шунда башын салган. Иҗади һәм актив кешеләр җәмгыятьтә һәрвакыт аз санда, гадәттә, алар башкалардан алда һәлак булалар һәм аларның юклыгы бөтен җәмгыять халәтендә чагыла. Иң яхшы кешеләр белән бергә киләчәк тә һәлак була. Әлбәттә, татарлар да шул ук тетрәнүләрне кичерәләр, репрессиягә дучар ителгәннәрне һәм сугышларда һәлак булганнарны исәпкә алсаң, аларның югалтулары башкаларныкыннан бер дә ким түгел, мөгаен. Әмма илнең киләчәге өчен җаваплылык интеллектуаль һәм рухи яктан хәлсезләнделелгән урыслар өстенә төшә.

Сугыштан соңгы чор рухиятне тергезүгә ярдәм итмәгән, чөнки меңләгән кеше коммунистик җәннәтнең котылгысызлыгын исбатлау белән шөгыльләнгән, ә талантлы галимнәрнең калган өлеше атом-төш һәм массакүләм юк итү коралларын уйлап табу эшенә керешкән. Үзгәртеп кору заманнарына Русиядәге фикер

үсеше гамәлгә яраклы берәр нәрсә тудырырга сәләтле түгел иде инде, ул Көнбатышның либераль идеяләрен йә үзләштерә, йә боза гына ала иде.

Русиядә социалистик әверелеш нигезсез булып чыкты. Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, СССР һәм башка илләрдәге социализм рәвеше Көнбатыш илләренә көчле тәэсир ясады, ул илләр, моннан сабак алып, кешелеклерәк була бардылар, кеше тормышын җиңеләйтә торган социаль технологияләр эшләп чыгардылар. Фашизмны җиңү кеше хокукларына игътибарны арттырды һәм ул Көнбатышның төп темасына әйләнде. Русиягә боларның берсе дә берничек тә кагылмады. Ул, социалистик идеяләрнең уңай йогынтысыннан җиңел генә качып, алардан иң яхшысын түгел, иң начарын — авторитар традицияләрне мирас итеп алды. Моңа җавап рәвешендәге либераль әверелеш тә тамыр җәя алмады. Русия Көнбатыш идеяләренең иң начарын алды. Ул хосусыйлаштыру һәм базар мөнәсәбәтләренә күчү чорында үз халкын талауны яшерер өчен идеологик пәрдә ролен үтәде. Дәүләт рухын байлык җыюга омтылыш алмаштырды. Бернинди бөеклек тә, бернинди рыцарьлык та юк — акча, бары тик акча гына. Акча тормышның да, сәясәтнең дә, хакимиятнең дә асылына әверелде. Икътисад кемдер хезмәт итеп акча эшләсен өчен кирәк. Хакимият исә тагын да күбрәк акча эшләп алу өчен кирәк. Әгәр син ярлы икән, димәк, бу тормышка лаек түгелсең. Халык исә куллanучы һәм җитештерүче буларак кына яши. Иң яхшы гамәл — бай булу, теләсә нинди ысуллар белән баеп калу. Ярлы — мескенлек синонимы. Дәрвишләр кадерсез. Рибачы комсызлыгы калган барлык идеяләрне һәм идеалларны — мәмләкәт, туган ил, намус-вөҗдан, хәтта Русиягә аеруча хас экспансия рухын да алмаштырды. Чын урыслар «Намус кушканча яшәргә!» таләп иткәннәр иде. Бүген моңардан кычкырып көләләр генә. Коточкыч әверелеш... «Русия җаны буржуаз җан түгел, ул алтын-көмешкә баш ими, аны менә шуның өчен генә дә чиксез яратырга була»,— дип дәртләнеп язган Николай Бердяев.  Бүген исә ул болай дип язмас иде. Урыслар алтын-көмеш хакына үз культураларындагы барлык затлы нәрсәдән йөз чөерделәр. Бу чирне «яңа урыслар» гына йоктырсалар бер хәл, әмма «яңа татарлар» да, башкалар да шул ук акча туплау юлына бастылар. Халыклар «алтын бозау» токтынына әверелделәр.

Сәясәт — электоратны алдауга, хакимият — бер олигархны икенчесе белән алмаштыруга, икътисад ил байлыгыннан илдән акча сыгу чарасына әверелде. Русия «олигархлары» дөньяның иң бай кешеләре булып чыктылар. Моның белән горурланып та булыр иде, тик бер сорау килеп туа: Русиянең бөтен бюджеты бер Нью-Йорк бюджетына тиң заманда болар моңа ничек ирешкәннәр соң? Нишләп алар шулкадәр бай, ә Русия шулкадәр ярлы соң? Абрамович 2003 елда Бөекбританиянең иң бай кешесе дип танылды. Гасырлар буена байлык җыйган, дөньяга капитализм тәгълиматчыларын биргән, ирекле базар үрнәге булган һәм ахыр чиктә колонияләрне талаган Бөекбритания Абрамович кебек «даһи» икътисадчыны тудыра алмаган булып чыга түгелме?!

Мөхәммәд пәйгамбәр әйткән: «Әгәр бәндәнең алтын сибелгән бер даласы булса да, ул аның икенчесен тели, икенчесеннән соң — өченчесен. Аның нәфесен бер уч туфрак кына басачак».

Алтын-көмеш культы — җәмгыятьнең нигезен корытучы, әдәп-әхлакны җимерүче, иң түбән инстинктларны кузгатучы ул. 2003 елның сентябрендә Санкт-Петербург шәһәрендә җиде скинхед 6 һәм 7 яшьлек таҗик кызларын үтерделәр. Аларның аналары исән калды. Скинхедлар аларны арматура таяклар белән кыйнаганнар, пычак кадаганнар, балта белән чапканнар, шулар арасында Дмитрий Хәйретдинов дигән адәм дә бар, мөгаен, татардыр. Судта алар «эч пошканнан чегәннәрне кыйнарга киттек» дип белдергәннәр. Русия һәм татарлар гүя мәрткә киткәннәр, бу йокыдан уяныр өчен тагын нинди хурлык кичерергә кирәк микән соң?

Көнбатышка ияру Русиядә бөтенләй бозык рәвеш алды. Бер яктан, матбугатта Көнбатышка каршы фикерләр ачыктан-ачык яңгыраса, икенче яктан, Көнбатыштан кирәксез нәрсәләрне: куллану культурасын, көчләп тагылучан рекламаны алдык. Голливудның атаклы актеры Колин Фаррел Александр Македонский турындагы фильмда коточкыч бер сүз әйтә: «Акча белән ант итеп әйтәм, бу бик кайгылы хәл». Алла белән ант итеп тә алтын-көмешкә табынган күпчелектән аермалы буларак, ул бик ихлас иде. Барлык «акчалы» Русия, аңа ияреп, бу гыйбарәне кабатлый ала: «Акча белән ант итәм». Әмма шул ук вакытта нәкъ менә Көнбатыш илләре байлык туплау рухын җиңәргә тырышалар, әмма Русиядә андый омтылыш юк. Тормышның сыйфаты матди чыгымнарга турыдан-туры бәйле түгел. Матди чыгымнарны чагыштырмача аз тотып, чиксез күп энергия һәм ресурслар сарыф итмичә генә дә тормышның югары дәрәҗәсенә ирешеп була. «Базар бозык материализмны, икътисад һәм икътисади сәбәпләр — кеше тормышындагы төп көчләр дигән ышанычны таратты».

Борынгы грек философы Сократ бервакыт Афинада агорага юл тоткан, анда Эллада җитештергән бөтен нәрсә сатыла икән. Боларны күреп Сократ кычкырып җибәргән: «Мондагы күпме әйбернең миңа кирәге юк!»

Көнбатыш исә ясалма тагылган яшәү рәвешен табигый яшәү рәвешеннән аерырга өйрәнә. Ул алтын-көмешкә табынудан котылырга тырыша. Көнбатышта гаять зур икътисади проектлар корыла, алар байлык

туплау рухыннан бигрәк рухият дәрәҗәсен чагылдыра. Билл Гейтс дөньядагы иң бай кеше генә түгел, ул башка кешеләрне баета торган идеяләргә һәм технологияләргә дә бай. Аның компьютер эшләнмәләре бөтен дөньяны үзгәртте. Аңарда Чыңгыз хан рухы — экспансиягә, яңа ачышларга омтылыш, культураларны коммуникация пәрәвезе ярдәмендә берләштерү рухы бар. Мондый кешеләр акчадан өстен, алар алтын-көмешне үз максатларына буйсындыра алганнар. «Финанс» сүзе — кол сүз; ул гражданлык җәмгыятенә билгесез»,— дип әйткән Жан Жак Руссо һәм мең кат хаклы булган.

Ә соң минем хөкем
Нәрсәләргә үтми? Бер демондай
Шушыннан мин хуҗа дөньяга;
Телим икән — сарайлар салыныр;
Шат нимфалар килер көлә-көлә
Сокландыргыч бакчаларыма;
Бар музалар мине мактап җырлар,
Азат даһи миңа кол булыр,
Изгелек һәм йокы белмәс хезмәт,
Юашланып, миннән бүләк көтәр.
Бер сызгырсам, күндәм һәм кыюсыз
Шуышып килер канлы явызлык,
Ул кулымны ялар, күзләремә
Карар, белер өчен теләгемне.
Бар да тыңлар мине, мин — һичкемне;
Үз көчемне беләм: миңа җиткән
Шуны белү...
(Үзенең алтынына карый.)
Күп тә түгел кебек,
Тик кешенең күпме ваемының,
Алдау, ялыну, нәләт, күз яшенең
Авыр тарта торган вәкиле ул...
Мин патшалык итәм! Сихри нур бу!
Көчле, күндәм миңа мәмләкәтем;
Анда бәхтем, анда даным минем!

*А.С.Пушкин. «Саран рыцарь»*

Русиянең интеллектуаль яктан һәлакәтчел рәвештә түбәнгә тәгәрәве — илнең иң төп бәласе диярлек. Урыс культурасының элеккеге бөеклеген бик күпләр илне тергезүнең гаранты дип күрсәтәләр. Әмма үткәннәргә әйләнеп карау, бөек фикер ияләрен, урыс әдәбиятының, философиясенең, фәненең алтын гасырын искә төшерү тагын да күңелсезрәк уйларга китерә. Бүген үткәннәр белән тиңләшерлек нәрсә юк. Гаять көчле мәдәни потенциал иҗтимагый фикерне тергезүгә этәргеч ясарга тиеш дигән өмет күңелдә пыскып тора. Тормыш күрсәткәнчә, ыргылыш ясарга әзер затлар, матди байлыкка түгел, рухи байлыкка омтылучы кешеләр булган очракта, бу — мөмкин хәл. Дәүләт «саран рыцарь» принципларына таянып яши алмый. Иҗтиһад рухы кирәк. Элек иң талантлы һәм иң актив кешеләрне үзенә туплап, бу вазифаны башкала үти иде. Бүген исә Мәскәү баю һәм урлашуның гәүдәләнеше булып тора.

Мәскәү метрополиягә бик охшаган, аның тормышы төбәкләр белән чагыштырганда бик күпкә яхшырак һәм ул күбесенчә төбәкләр исәбенә яши. Ул үзенә финанс агымнарын гына түгел, мәгълүмат агымнарын да, транспорт һәм энергетика системаларын да туплаган. Бу күзлектән караганда Русия империя булып күренә. Мәскәү үз-үзен тәэмин итә һәм махсус шартларга, өстенлекләргә ия булу аркасында илнең тормышын аңлый алмый, әмма ул-бу була калса, шул өстенлекләр өчен дәүләтнең бөтен куәтен җигеп көрәшәчәк. Санкт-Петербург та илнең ниндидер альтернатив интеллектуаль үзәге ролендә дәгъва итә алмый. Ул башкала да, башкала түгел дә, ул — башкала турындагы истәлек, мин-минлек чиренә нигезләнүче ниндидер бер мираж. Ә төбәкләр исә үзләренең начар тормышыннан зарланып яши.

Тарих Русияне һаман шул иске эзенә әйләндереп төшерә. Ил үз икътисадында индустриаль баскычтан чимал баскычына төште. Сәнәгать техник яктан артка калды һәм, нигездә, сугыштан соңгы технологияләр буенча эшләвен дәвам итә. Русия үз авиациясеннән ачыктан-ачык баш тарта, автомобиль сәнәгате җан тәслим кылырга җыена, электроника конкуренциягә бөтенләй сәләтсез, суднолар, моторлар, приборлар төзелеше инерция буенча билгеле бер вакытка кадәр генә яшәячәк. Авыл хуҗалыгы тармагы ташландык хәлдә. Башка илләр аграр мәсьәләне берничә гасыр элек хәл иттеләр, Русиягә аны бүген үк хәл итәргә кирәк; әмма хөкүмәтнең бу тармакны язмыш кочагына ташлавы ачык күренеп тора. Мәгълүмат революциясе башланган иде, ләкин әллә кайда еракта туктап калды. Без илнең примитиврак дәрәҗәгә кайтып баруын күрәбез. Бу икътисадның барлык тармакларында да күзәтелә. «Өченче илләр»дәге кебек үк төп басым чимал сатуга, химияне үстерүгә һәм армияне ныгытуга ясала.

Яңа интеллектуаль-мәгълүмати эра дөньяви юнәлешләрне билгеләде, алга киткән илләр шулар буенча киттеләр, Көньяк-Көнчыгыш Азия илләре дә аларга иярде. Ә Русия аңа кадәрге этапларны да: аграр революцияне дә, индустриальләштерүне дә тәмамламаган әле. Ул цивилизацияләр арасындагы бусагаларда тоткарланып калды. Әмма иҗтимагый фикер иң аяныч хәлдә, ул илнең чимал юлыннан үсеше белән килешә. «Акыллы фикер» ияләреннән шикләнә башладылар.

Дөньяның заманча икътисады интеллектуаль өлкәдә гаять зур сикереш исәбенә үсә. Икътисадның ыргылышлы тармаклары барлыкка килү финанс манипуляцияләре белән дә, компьютерлаштыру белән дә түгел, нәкъ менә интеллектуальләшү белән аңлатыла. Дөньяның киләчәге чимал илләре кулында түгел, интеллектуаль илләр кулында. Теләсә нинди илнең нормаль яшәеше өчен банк яисә энергетика системасына караганда белемнәр системасы мөһимрәк. Кеше капиталы акча капиталын алмаштырып килә. «Белем — алыштыргысыз чара, хәзерге икътисадның төп ресурсы буларак, чималга, хезмәткә, вакытка, пространствога, капиталга һәм башка ресурсларга ихтыяҗны киметә һәм аның кыйммәте арткannan-арта бара». Мәгълүмат — бетмәс-төкәнмәс ресурс, киләчәк цивилизация чималы ул. Домна миченнән яисә завод линиясеннән аермалы буларак, белемнән бер үк вакытта берничә компания файдаланырга мөмкин. Һәм бу компанияләр әлеге белемнәрне тагын да арттырырлык итеп куллана алалар. Иске стратегия акча әйләнешенә корылган, әмма белемнәргә нигезләнү күпкә отышлырак. Инвестицияләр төрле җайланмаларга гына һәм бигрәк тә чималга гына түгел, белемнәргә кертелергә тиеш. Миңа Греция утравы Родоста бер конференциядә булырга туры килде, бу утрауда электр энергиясенең 75% ы өй түбәләренә куелган кояш батареяларыннан алына. Аларга нефть тә, газ да кирәк түгел, аларга заманча кояш батареялары кирәк. Аларны чимал чыганаклары борчымый — кояш гел яктыртып тора, әйләнә-тирә табигать өчен дә эчләре пошмый. Килер бер көн: бензин двигателен водород двигателе алмаштырыр, һәм бөтен нефть чыгару һәм нефть эшкәртү сәнәгате эшсез калыр.

Белемнәр ресурсларны да, аларны күчерү-ташу эшен дә алмаштыра. Телекоммуникациянең заманча төрләре барлыкка килү тегендә-монда баруга киткән чыгымнарны киметә, өйдә генә яисә зур шәһәрләргә бармыйча гына эшләү мөмкинлеге тудыра. Интернет булганда хезмәт коллективын бер урынга җыюның кирәге дә калмый, хезмәткәрләрне компьютер аша виртуаль коллективка берләштереп, эш урынын өйдә ясау арзанракка да төшә. Кешеләр төрле илләрдә яшәп тә бер үк оешмада эшләргә мөмкиннәр. Бу күренеш исә фирмаларга, үз өеңә карашны, тормыш рәвешен үзгәртә. «Электрон коттедж» һич көтмәгәндә гаять зур әһәмияткә ирешә. Үз-үзеңне тәэмин итү үсеше, бизнесның яңа структураларын тарату, җитештерүне автоматлаштыру һәм демассификация «үз өең киләчәкнең үзәк берәмлегенә — билгеле бер икътисади, медицина, мәгариф һәм социаль вазифалар үтәүче берәмлеккә әверелүенә» китерәчәк.

Яңа интеллектуаль-мәгълүмати эра глобальләшүне дә, шулай ук культуралар дифференциациясен дә көчәйтә. Глобальләшү милләтчелекнең искерүе хакында сөйли. Аңа алмашка планетар аң килә. Транснациональ корпорацияләр, Европа Берлеге, халыкара финанс структуралары, коммуникациянең яңа чараларын төзүчеләр, табигать өчен көрәшүчеләр, язучылар һәм сәнгатькярләр — болар бар да шушы бөтендөнья тенденциясе чагылышы булып торалар да инде. Аерым илләрнең хөкүмәтләре бәйсез карарлар да кабул итә алмый, алар бу карарларны дөньядагы хәлләргә — сәясәт, финанс, энергетика, хәтта мәдәният өлкәләрендәге вакыйгаларга яраштырырга тиеш.

Шул ук вакытта дөнья көннән-көн төрләнә, массакүләм колачын җуя бара. Алдынгы җитештерүчеләр инде бүген үк үз эшчәнлеген алдан билгеләнгән стандартларга түгел, индивидуаль заказларга кора. Заманча технологияләр нәтиҗәле җитештерүне заказчының анык ихтыяҗына туры китерергә ярдәм итә. Италиянең зур булмаган бер предприятиесендә мин бер үк конвейердан төрле заказчылар таләбенә яраклаштырылган төрледән-төрле тәрәзәләр һәм ишекләр төшүен күрдем. Унификация үткән заманда кала, икътисадны маркетизацияләү дә тәмамланды һәм киләчәктәге үсеш җитештерүнең массакүләмлегенә түгел, ә кулланучылар ихтыяҗларының күптөрлелегенә корыла. Димәк, моның белән бергә корпорацияләр кечерәя барачак, чөнки кечкенә үлчәмнәр үзгәргән шартларга яраклашуны тизләтә. Корпорацияләр икътисади нигезләрен югалтачак. Дөньяның алдынгы корпорацияләре саф икътисади предприятиеләрдән социаль предприятиеләргә әвереләләр — алар күп максатларны күз алдында тоталар, шулар арасында социаль һәм экологик максатлар табыш мәсьәләсе белән бертигез әһәмияткә ия. Алдынгы компанияләрнең уңыш күрсәткечләрен төзегәндә табышның социаль проектларга тотылган өлеше исәпкә алына, предприятиеләрнең социаль җаваплылыгына бәя бирелә. Икътисадның табигать һәм тирә-юньдәге халык белән гармониясе корпорацияләр уңышында әһәмиятле фактор булып тора.

Дифференциация массакүләм мәгълүмат чараларына да кагылды. Көнбатышта конкрет кулланучыга юнәлтелгән һөнәри, этник, төбәк үзенчәлекләрен исәпкә алучы аз тиражлы газеталар массакүләм газета һәм журналларны кысып чыгара башлады. Киң катлауга исәпләнмәгән кечкенә журнал бик тиз аякка баса. Радио һәм телевидение базарында да шул ук хәл. Кабель телевидениесе чын революция ясады — һәркем

үзе теләгән программаны сайлап ала. Массакүләм мәгълүмат чаралары эпохасы индивидуальләшкән мәгълүмат чаралары тарафыннан кысрыклана.

Сәяси өлкәдә дә үзгәрешләр көтелә. Дәүләт төзелмәләрен һәм карарлар кабул итү процессын үзәктән аеру төп юнәлешкә әверелә. Бу Европа Берлеге мисалында ачык күренә, анда хәтта Франция тибындагы унитар дәүләтләр дә хакимиятне мөмкин кадәр түбәнрәк баскычларга тапшыра. Империализм — индустриаль җәмгыять җимеше, ул бөтен халыкларны гомуми акча системасына тартып кертеп глобаль интеграцияләнгән базар җитештерүен оештырды, әмма аның вакыты узды. Империализм дөнья ресурслары исәбенә яшәде. Хәзерге заман цивилизациясе интеллект исәбенә яши.

Сәясәттә механик күпчелек түгел, ә азчылыкның һөнәри, этник, сексуаль, төбәк, дини мәнфәгатьләре күбрәк исәпкә алыначак. Бүген парламентларда һәм хакимият органнарында барлык этнослар да вәкиллеккә ия түгел, хатын-кызларның вәкиллеге дә җәмгыятьтә тоткан урыннарына тәңгәл түгел, яшьләр, дини общиналар үзләреннән башка кабул ителгән законнар буенча яшиләр. Мәнфәгатьләрнең күптөрлелеген исәпкә алу коммуникациянең яңа чаралары ярдәмендә мөмкин булачак. Инде мәңгелеккә үткәндә калган кебек тоелган турыдан-туры демократия идеясе сәясәткә яңадан әйләнеп кайтырга мөмкин. Үз заманында Жан Жак Руссо, вәкиллекле демократиягә аклау тапмыйча, аны тәнкыйтьләгән. «Вәкиллек идеясе — заманча идея, ул феодаль идарәдән — әлеге гаделсез һәм мәгънәсез идарәдән килә, анда кешелек кимсетелгән, ә кеше үзе мәсхәрәләнгән»,— дип язган ул. Ул халыкның турыдан-туры идарәсенә тиң бүтән идарә күрмәгән. Аның өчен суверенлык ул — уртак ихтыяр, ә ихтыярны исә ниндидер аерым кеше чагылдыра алмый. «Халык депутатлары нигез түгел һәм алар халык вәкилләре була алмый, алар халыкның комиссарлары гына; алар бернәрсә хакында да катгый карар чыгара алмый; халык шәхсән үзе расламаган теләсә кайсы закон гамәлгә яраксыз; бу хәтта закон да түгел. Инглиз халкы үзен иректә халык дип саный һәм бик нык хаталана; ул парламент әгъзаларын сайлау вакытында гына ирекле; алар сайлану белән халык колга әверелә, ул юкка чыга». Швейцариядә закон чыгаручыларның карарлары даими рәвештә үткәрелүче референдумнарда раслана. Бу бер дә очраклы хәл түгел. Турыдан-туры демократия тарихта техник сәбәпләр аркасында вәкиллекле демократиягә алмаштырылган, электрон җәмгыять турыдан-туры демократиягә әйләнеп кайту мөмкинлеге ача.

Дөньядагы шушы тектоник күчешләр җирлегендә Русия сәясәте өметсез рәвештә артта калган сәясәт булып күренә. Бу өлкәдә үткәрелүче реформалар кешелек үсешенең төп юнәлешләренә каршы килә. Бөек борылыш — Петр мирасы — үзен империячел үткәннән баш тарту, демократик институтларны үстерү, чималга нигезләнгән фикер йөртүдән интеллектуаль фикер йөртүгә күчү аркылы җиңеп чыгуны таләп итә. Кемдер Русияне акча ярдәмендә коткарырга өметләнә, кемдер көч төзелмәләрен ныгыта, әмма Русияне аның хөр рухы гына коткарачак, ә хөр рух исә заманча университетлары һәм бәйсез төбәкләре булган ирекле җәмгыятьтә генә туарга мөмкин!

## Тарихны җиңеп чыгу

*Фәкыйрьләргә намусыңны син саткан чакта,*
*Малың мактап сата күрмә син хәрам хакка.*
*Барыбер бит иң югары — Ходай Тәгалә!*
*Ахырзаман җиткәч, басу ялварыр сиңа:*
*«Җый уңышым! Җимешемне авыз итсәнә?»*

*Күккә ирешеп дөньяда булсаң да маллы,*
*Онытсаң әгәр фәкыйрьне һәм горабаны,*
*Хәерчегә тиен тапмасаң авыр көннәрдә,—*
*Барлык кылган шәфәгатең очар көл булып,*
*Юар барлык изге эшең яңгырлы болыт.*

А.С.Пушкин. «Подражание Корану»
Зөлфәт тәрҗемәсе

Русиядәге кризисның асылы — империячел традицияләрнең, аның белән бергә бөек державачылыкны яклаучы һәм аклаучы культураның да бөтенләй таркалуында. Империализм һәм бөек державачылык берберсеннән аерылгысыз яки, Н.Бердяев әйтмешли, «империячел сәясәт — теләсә кайсы бөек державачылыкның ачы язмышы». Урыс мәдәниятенең фаҗигасе — аның милли мәдәният буларак вазифасының дәүләт сәясәтенә, бөек державачылыкны ныгытуга, югары күтәрүгә, каһарманлаштыруга, мифлаштыруга туры килүендә. Урыс мәдәниятенең хәтта Бөек Петр, Полтава сугышы турындагы әсәрләре, Лев Толстойның «Сугыш һәм солых»ы кебек гуманлы, чын шедеврлары да, теләсәләр-теләмәсәләр дә, мессианлык рухын, урысларның дөнья тарихындагы аерым ролен (бусы дөрес нәрсә) хуплыйлар. Кызганыч ки, бөтен әдәбият,

публицистика, рәсем сәнгате, философия ялган хәзинәләр тудыручы ялган тарих белән сугарылган. Урыс мәдәнияте дәүләтчелеккә артык нык бәйләнгән һәм урыс кешесенең аңы да дәүләт идеологиясеннән тора. Н.Бердяев болай дип язган: «Урыс кешесе мин Русияне коткарырмын дип түгел, ә Русия мине коткарыр дип уйлый. Урыс кешесе үзен беркайчан да оештыручы дип тоймый. Ул үзен оештырганга күнеккән». Мондый психология дәүләтчелекне үзгәртеп коруга түгел, ә бөек державачылыкны торгызуга ярдәм итә. Драма шунда ки: империянең тарих ресурслары беткән, ә аң исә әле һаман мессианчыл булып калган. Вакыйгалар, иҗтимагый аңны җәрәхәтләп, психологиядән алда йөри. СССР таркаласын яисә Берлин стенасы җимereләсен кем дә булса ярты ел яки бер атна алдан әйтеп бирер идеме икән? Хәтта бу хактагы уйны да теләсә кем нәфрәтләнеп кире кагар иде. Шуңа да карамастан бу вакыйгалар барысы да булды. Дөнья хәзер бик хәрәкәтчән, искергән төзелмәләр күз алдында юкка чыга, ә кешеләр аңындагы стереотиплар һаман яши.

Русия тарихында әле беркайчан да аның дәүләт корылышы турындагы мәсьәлә бүгенгечә кискен тормый иде. СССР таркалу гади генә вакыйга түгел, бу — «Зур Русия»нең таркалуы. СССР һәм Русия — төрле дәүләтләр түгел, чикләре төрле булган бер дәүләт. Беренче карашка дәүләт биләмәсенең кечерәюе ул кадәр әһәмиятле кебек тә түгел, Русия барыбер чиксез зур ил булып кала лабаса. Чынлыкта исә бу факт гаять катлаулы сәяси коллизияләр китереп чыгара. Территория дәүләт чикләрен дә, мәдәни традицияләр таралу чикләрен дә билгели, икътисад халәтенә дә, халыкара мөнәсәбәтләргә дә йогынты ясый. Территория — дәүләтнең тормыш мәнфәгатьләре символы. Территория турындагы бәхәсләрнең иң рәхимсез конфликтлар һәм сугышлар кузгатуы очраклы түгел.

XVI гасырдан башлап, нигездә Казанны яулап алганнан соң, илнең бөтен хәрби, интеллектуаль куәте һәм икътисади ресурслары территорияне киңәйтүгә юнәлдерелгән. Русия тарихында каһарманнар — басып алучылар алар: Ермак, Петр I, Суворов һәм башкалар, шулай ук булачак баскакларны конкрет материал белән тәэмин итүче географлар, этнографлар һәм миссионерлар. Кайбер халыкларның һәм илләрнең үзләре теләп кушылуы мәсьәләнең асылын үзгәртми — Русия үз биләмәсен һәм йогынты даирәсен XX гасыр азакларына кадәр киңәйтте. Әфганстан бу сәясәтнең соңгы сәхифәсе булды.

СССРны үзенең сәяси амбицияләре хакына таркаткан кеше Русиядә милли каһарман була аламы? Риторик сорау. «Урыс җаны» үзенең төпкелендә җиренең бер мыскалын да бирергә риза түгел, хәтта Курилдагы бәләкәй, ташландык япон утрауларын да.

Русия территориясен йөзләгән еллар буена берөзлексез, көн саен киңәйтеп тору үзенчәлекле сәяси культура тудырган. Державачылык нәтиҗә дә, йомгак та түгел, ул урыс җәмгыятенең канында яши. Шуңа күрә дә демократлашу процессы һәм элеккеге барлык күзаллауларның җимерелүе Русия аңы өчен коточкыч фаҗига булды. Милли идеология (урыс марксизмын да кертеп) илнең территориясен киңәйтүгә корылган иде, асылда исә ул дәүләт экспансиясен нигезләү иде. Бу хәл дәүләт яшәвенә дәрт өстәде һәм күпсанлы корбаннарны аклады. Традицион урыс фикере территорияләрне кыскарту турында уйламый да, моңа юл да куймый, хәер, ул шулай ук хакимиятне үзәкләштерүдән котылуны да, хокук белән канунның өстенлек итүен дә күздә тотмый.

Сүлпән баручы реформалар, халыкның тормыш дәрәҗәсе начараю, илнең абруе төшә бару шартларында Көнбатышка каршы карашлар барлыкка килү котылгысыз иде. Дәүләт Думасына 1993 елгы сайлаулар күрсәткәнчә, «дәүләт идеяләре, аеруча үзләренең иң чик реинтеграция рәвешләрендә Русиялеләрнең күп өлешен үзенә тарта башлады. Милли-патриотик партияләрнең һәм хәрәкәтләрнең популярлыгы ике ел ярым эчендә 55 процентка артты». Шул ук вакытта әлеге сайлаулар тагын шунысын да күрсәтте: «Көнбатыш демократиясенең универсаль хәзинәләре, коммунистик үткәннең хәзинәләре кебек үк, бик тиз генә массакүләм аңның күләгәсенә чигенде». Дәүләт Думасына 1995 елгы сайлаулар бу юнәлешне раслады һәм беркетеп куйды. Империячел, державачыл, шовинистик, милли-патриотик идеяләр популярлашты. Аннары ачыктан-ачык фашистик концепцияләр барлыкка килде. «Безнең урыс ата-бабаларыбыз безнең илне татарлар яисә әрмәннәр өчен дә, чеченнар яисә яһүдләр өчен дә төземәгәннәр, моны ачык аңларга кирәк,— дип яза Александр Севастьянов.— Алар илне иң беренче чиратта безнең өчен, урыслар өчен, үзенең оныклары өчен төзегән». Русияне урыслар дәүләте һәм урыслар өчен дәүләт дип аңлый ул. «Бернинди дә «совет халкы» булмаган кебек үк, табигатьтә бернинди дә бердәм «Русия милләте» юк, болар барысы да тагын бер миф кына. Урыслар бар, урыс булырга теләгәннәр бар, урыс кешеләренә дустанә мөнәсәбәттә торучылар бар, шулай ук дошманнар да бар. Безнең илдә башлангыч вазгыять шундый. Русиядә милли-капитализм 100% ук саф урысныкы була алмый, булырга тиеш тә түгел, ә менә 82% була ала». Фашист Германиясендә яһүд геттолары да тиз генә барлыкка килмәгән. Табигатьтә «саф» фашизм була алмый. Скинхедлар мисалында без фашизмның табигате кайда да бер үк икәнен күрәбез. Ул яһүдләрне, «Кавказ чырайлы» кешеләрне кыйнап ташлаудан башлана, аннары урыс булмаган барлык кешеләргә каршы чыга, аннары, ниһаять,

үзләре белән килешмәгән урысларга кадәр барып җитә. Искәрмәләр булмый ул. Бүген җәмгыять таяныч ноктасын эзләп үрсәләнә.

Сәясәтчеләр дөреслектән куркалар һәм аек акылны бөек державачыл риторика, мифлар иҗат итү белән алмаштыралар. Алар Җир шарының җидедән бер өлешен тәшкил итүче Русиянең иксез-чиксез киңлекләре турында горурланып сөйлиләр. Ә бит заманында Петр Чаадаев болай дип язган: «Урыслар, чынлап торып, кешелек белеменең кызыклы тармагына әйләнү өчен илнең гаять зур булуы гына да җитә дип уйлыйлар микәнни?.. Бу — халык горурлыгының үз-үзен алдап юатуы гына. Һәм фән әлеге күренешне киләчәк буыннарга сабак булырга тиешле халыкларның ялгышу мисалы буларак билгеләп үтәчәк». Үз-үзләрен алдап юату дәвам итә. Кремль коридорларының патшалар заманындагы ялтыравыгы күзләрне чагылдыра, җанны татлы хыяллар белән агулый һәм җәмгыятьнең мескен хәлен каплап тора. Ә хакыйкать шунда ки, «үлүчеләрнең чиктән тыш артуы, ә туучыларның чиктән тыш кимүе күзәтелгән 12 ел эчендә Русия 13 миллионнан артык кешесен югалтты (бу Уралдагы алты төбәк халкының гомуми санына тиң). Илнең тыныч заманнардагы демографик тарихы моңа кадәр шундый һәлакәтчел хәлне бары тик бер генә тапкыр күргән — ул да булса 1933 елгы ачлык галәмәтләре». Илдән ел саен 30 — 40 мең белгеч китә (югары уку йортларын тәмамлаучыларның 10% ы), ягъни иң югары профессиональ әзерлекле кешеләрдән генә торган бөтен бер шәһәр башка илләргә күчеп китә дигән сүз. Моны революциядән соңгы елларда интеллигенциянең илне бөтенләй рухи фәкыйрьлектә калдырып китүе белән хәтта чагыштырып та булмый. Русия фәне һәм тулаем алганда бөтен рухи даирә бетүгә йөз тота, гәрчә Русия 100 кешегә туры килүче галимнәр саны буенча башка илләрдән артта калмаса да. Әмма эзләнүләргә һәм фәнни эшләнмәләргә тотылган чыгымнар буенча ул Германиядән, Япониядән һәм Кореядан гына түгел, Төркиядән, Польшадан, Чехиядән дә артка калып, үсеп килүче илләр белән бер рәткә — Румыния белән бер тирәгә басты.

Русия кеше үтерүләр саны буенча Колумбиядән һәм ЮАРдан соң өченче урында тора. Йорт-җирсезләр саны 4 миллион кешедән артып китте. Акчаның кискен рәвештә җитмәве авыл хуҗалыгын искереп артка калуга дучар итә. Йорт хайваннарының барлык токымнары, мөгезле эре терлекне, дуңгызларны, сарыкларны, кәҗәләрне һәм кошларны да кертеп, баш саны буенча кимегәннән-кими бара. Авыл халкы күпләп-күпләп шәһәргә күчә. Русиягә азык-төлекне читтән кертү исә Африка һәм Азия илләре дәрәҗәсенә җитте. Әлеге күрсәткеч буенча Русия Бангладеш, Камерун белән бер рәткә басты, әмма Марокко, Оман, Пакистан илләрен узып китте. Хурлыклы статистика. «Металл эшкәртү кулланылучы машина төзелешенә инвестицияләр кискен кимеде. Икътисад нормаль эшләгән чор белән чагыштырганда, аларның капитал салуларның гомуми суммасындагы өлеше өч тапкырга кимеде. Кайчандыр сәнәгатьтә иң алдынгылардан берсе булган бу тармакка инвестицияләр күләме 12 ел эчендә тугыз мәртәбә кимеде, бу илдә индустриянең таркалуын аңлата». Төзелеш тә кимеп бара. Чималны читкә чыгару гына сөендерә. «Экспортында чимал чыгару сәнәгате продукциясе 60% тәшкил иткән Русия минераль чимал сатучы атаклы илләрдән: Норвегиядән (40%), Боливиядән (27%), ЮАРдан (26%) алда бара, бары тик Алжирдан (80%) гына калыша». Ләкин нәкъ менә шушы өлкә илнең киләчәге өчен аеруча куркыныч, чөнки икътисад нефтьтән башка яши алмый башлый һәм чималга бәяләр кинәт төшкән очракта коточкыч һәлакәт кичерергә мөмкин. Русиянең тышкы бурычы, җан башына күчереп исәпләгәндә, дөньяда иң зур бурычлардан берсе. Күрсәткечләрнең барысын да кушып санасаң, гомумартка калу көн кебек ачык.

Проблемаларның төп сәбәбе Русиягә каршы ниндидер дошман гамәлләр кылынуда да, идарә итә белмәүдә дә түгел, гәрчә боларны да исәптән алып ташларга ярамый. Хикмәт традицион аңда яки, дөресрәге, империячел инстинктта, ул, илнең җелегенә үтеп кереп, тиешенчә үсәргә комачаулый.

Советлар Союзы таркалганда, элеккеге Русия дә таркалды һәм, табигый ки, яңа дәүләтчелек үзен билгеләргә тиеш иде. Дәүләтчелек ... 

Советлар Союзы таркалганда, элеккеге Русия дә таркалды һәм, табигый ки, яңа дәүләтчелек үзен белдерде. «Русия Федерациясе Президентының Федераль җыенга милли куркынычсызлык буенча юлламасы»нда «яңа Русиянең үзбилгеләнеше» турында әйтелү очраклы хәл түгел. Әмма теләсә нинди үзбилгеләнеш — дәүләтнең концептуаль нигезләрен эшләүгә бәйле бик авыр процесс. «Яңа Русия» Петрга кадәр замандагы чикләрендә калды. Дәүләтнең биләмәсе кечерәю — сан факторы түгел, сыйфат факторы ул. Зур сәясәткә тәэсир итүче бөтен үлчәмнәр нигездә үзгәреш кичерделәр. Икътисади һәм демографик потенциал кискен кимеде. Көньяк өлешнең Русиядән аерылып чыгуы аркасында илнең икътисады чыгымлырак була башлады. Климат кырысрак булып чыкты, ә коммуникация проблемалары (аралар озынлыгы, тарифларның икътисадка йогынтысы һ.б.) нигездә шул килеш калды. Русиянең Кара диңгездәге, Каспий һәм Балтыйк диңгезендәге хәле бик зур үзгәреш кичерде һәм хәлиткеч позициясен югалтты. Әмма иң мөһиме — кыйммәти юнәлешләрнең үзгәрүе. Русия биләмәләрен киңәйтү идеологиясеннән аларны кору-төзекләндерүгә күчәргә мәҗбүр, ләкин ул бу гамәлгә әзер түгел.

Демократия мөнәсәбәтләре һәм базар шартларына күчү илнең география, климат һәм икътисад якларыннан күптөрлелеге белән элеккегедән күбрәк исәпләшүне таләп итә. Илнең киң үлчәмнәре исә өстенлек булудан аның конкуренциягә сәләтен киметүче җитди җитешсезлеккә әверелеп бара. Русия хәзер ресурс-

ларның кими баруы, диңгезгә чыгу юлларының начарлануы шартларында яшәргә мәҗбүр, ләкин саклау мәҗбүри булган чикләр озынлыгы нигездә шул ук калды лабаса.

Русия стратегик геосәяси урынны — Евразияне биләп тора, бөтен бөек державаларның: АКШ, Кытай, Япония, Германия һәм башкаларның карашы шунда юнәлгән. Русиядәге эчке процессллар халыкара процесслар белән тыгыз бәйләнгән. Бу мин-минлекне кытыклый, чиксез тәкәббер амбицияләр уята, әмма бик күп нәрсә йөкли дә. Мондый геосәяси урында Русия бөек булырга тиеш, ләкин ул бөеклеген югалтты, шуңа күрә дә хәзер аның җаны бөек үткәнгә кире кайту омтылышы белән бүгенге коточкыч халәте арасында; патша пулатлары белән сасы исле, мескен югары белемле бомжлар арасында бәргәләнә.

*Бервакыт Аксак Тимернең бөеклеге турында сүз чыккач, шәһәр башлыгы болай дигән:*
*— Бу дөньяга күпме генә ханнар килеп китсә дә, Аксак Тимер кебеге булмас.*
*— Ул нинди генә бөек булып күренсә дә, дөя барыбер аннан зуррак,— дигән Хуҗа Насретдин.*

Соңгы елларда Русия үзендә элеккеге ССР Союзы язмышы кабатланудан куркып яшәде. Бу курку рациональ булудан бигрәк, мистик, фаталистларча курку иде, аны СССРны таркаткан өчен үзен гаепле санау хисе һәм моның өчен җәзаның котылгысызлыгын тою китереп чыгарды. Хәтта Ленин да Финляндия белән Польша бәйсезлеген үз ихтыяры белән түгел, аларны Русия тәшкилиятендә көч кулланып та калдырып булмаганга күрә генә таныган. Ата-бабалар гасырлар буе сугыш кырларында берничә буын халыкны корбан итеп җыйган илне Ельцин бер «Беловеж төне» эчендә таратып кайтты. Ул кылыч чыңлавын бокаллар чыңлавына алмаштырды. Аның бу гөнаһы гафу ителер микән?

Федераль органнар республикаларның теләсә нинди иң зарарсыз, әмма мөстәкыйль фикерләренә каршы ярсып чыктылар, субъектлар ягыннан теләсә нинди «итагатьсезлек»не сепаратизм дип кабул иттеләр. Сәясәтчеләр, идеологлар, язучылар, имеш, башланып килүче таркалуны туктатырга, «суверенлык парадларын» тыярга, республикаларны бетерергә, уйдырма каршылыкны көч кулланып бастырырга өндәделәр. Бөтенесе тылсымлы 82% ка (Русиядә урыслар 82%) өмет баглады. Бу санны кирәксә дә, кирәкмәсә дә тәкрарлап тордылар. Газетларда һәм фәнни мәкаләләрдә: «Русия — дөньядагы иң моноэтник ил!», «Дөньядагы бер генә илдә дә кече халыкларга илнең бөтенлегенә кул сузарга рөхсәт ителми!», «Держава кагылгысыз!», «Сепаратистлар китсен!», «Ку аларны, ку!» — дип ләззәтләнеп яздылар. Карашлар армиягә таба көннән-көн ныграк төбәлә барды — янәсе, бөтен мәсьәләләрне хәл итүнең иң ышанычлы чарасы шушы. Ахыр чиктә бу авазны ишетеп алдылар, һәм Чечняда сугыш башланды.

«Чечен синдромы», бер яктан, «державачылык» юнәлешен көчәйтсә, икенче яктан, армиянең мөмкинлекләренә һәм көч куллану алымнарына ышанычны какшатты. Күп кенә урыслар ниндидер бер мизгелдә Чечняны югалту белән ризалашырга әзер иде — СССР таркалуга күнгәннәр иде бит инде. В.Путинның Грозныйга ыргылышы аларда яңа өметләр уятты. В.Путин сәяси мәсьәләне хәрби юл белән хәл итәргә талпынды, ул «Гордий төенен» сүтеп тормыйча, кылыч белән кисеп кенә ташларга теләде, әмма нәтиҗәдә вазгыятьне катлауландырды гына. Илне идеологик буталчыклык басты. Халыкның демократиядән күңеле кайтты, әмма ул аннан баш тарта алмый иде инде. Көнбатышка каршы, Америкага каршы карашлар көчәйгәннән-көчәя барды. Фашизм да көч җыйды. Безнең җәмгыятькә либераль хәзинәләрне үткәрүчеләр буларак уң партияләр сәяси аренадан юкка чыктылар. Чырайлары телевизор экраннарында гына калган коммунистларның дәрәҗәсе төште. «Азатлыктан качу» башланды. Әмма Русия җирлегенә бик начар утыртылган либераль идеологиягә җавап рәвешендә барлыкка килгән державачылык юнәлеше дә өметләрне акламады. Кешеләр аңында хәрабәләр генә калды.

Фетнә чоры өчен котылгысыз булган каршылыклардан читкә китеп карый алсак, Русиянең үзенеке булган бердәнбер оригиналь идеясен — «Евразия цивилизациясе» теориясен күрербез. Биредә Русия Европа белән Азия арасында — каядыр уртада урнашкан мөстәкыйль цивилизация буларак килеп баса.

Н.С.Трубецкой, П.Н.Савицкий, Г.В.Вернадский җитәкчелегендә евразиячелекне башлап җибәрүчеләр Русия территориясен үз-үзен тәэмин итеп торырлык киңлек, үзенчәлекле дөнья, үзенчәлекле цивилизация дип санаганнар. «Элек Русия империясе дип аталган, хәзер СССР дип йөртелүче ул дәүләтнең милли субстраты булып әлеге дәүләттә яшәүче халыкларның күп халыклы үзенчәлекле милләт дип каралучы һәм әлеге сыйфатта үзенчәлекле милләтчелеккә ия булучы бөтен бер җыелмасы гына тора ала. Бу милләтне без — евразия милләте дип, аның биләмәсен — Евразия дип, аның милләтчелеген евразиячелек дип атыйбыз»,— дип язган Н.С.Трубецкой 1927 елда. Бу идеология Көнчыгыш белән Көнбатышны берләштерүгә түгел, киресенчә, аларны бер-берсенә каршы куюга юнәлдерелгән. «Без иң явыз дошманыбыз — роман-герман дөньясы һәм аның культурасы дигән фикергә күнегергә тиеш»,— дип тә язган Н.С.Трубецкой. Билгеле, евразиячелеккә нигез салучыларның фикеренә 20 — 30 нчы елларда Европадагы хәлләр — Германия-

дә һәм Италиядә фашизм баш калкыту да йогынты ясагандыр. Бүгенге вазгыять ул чактагыдан тамырдан аерылып тора, шуңа да карамастан евразиячелекнең бүгенге тарафдарлары шул ук рухтагы фикерләр әйтәләр. «Ике фронтта көрәш алып баруга әзер булырга кирәк»,— дип яза В.Ильин. Янәсе, беренче куркыныч Көнбатыш Европадан янаса, икенчесе — Кытайдан.

Александр Дугин Евразиянең төп дошманы дип «атлантчыларны», беренче нәүбәттә Кушма Штатларны саный. «Тарих мантыйгы һәрдаим төрледән-төрле дәрәҗәләрдә төп дуализмны — АКШ белән СССРны, Көнбатыш белән Көнчыгышны, Америка белән Русияне кабат-кабат чагылдырып тора. Икътисадта, сәясәттә, геосәясәттә, дини гыйлемнәрдә, мәдәнияттә ап-ачык, хәтта куркыныч төстә ачык бер антитеза бар: дөнья драмасы, континенталь дуэльның ике полюсы, физик һәм рухи континентларның бөек сугышы турында күзгә күренеп торучы сурәт». Хәзерге евразиячеләр җәмгыятькә каршы куярлык дошман эзләүгә корылган үз теориясен төзи.

Евразия идеологиясенең төп нигезе — территориаль принцип, ул, янәсе, территория үзендә урнашкан халыкларга яшәү шартларын көчләп тага. Һәм ул — абсолютка, ягъни динне дә, кешелек кыйммәтләрен дә үзенә буйсындыручы категориягә әверелә. Әлеге территориядән котылып та, аны үзгәртеп тә булмый, ул фаталь рәвештә синең язмышыңны да, хәтта дошманнарыңны да алдан билгеләп куя, сиңа баштан ук нәкъ шушы дошманнар насыйп, чөнки алар далада түгел, диңгез буенда яшиләр. Бу концепциядә кеше бөтенләй юкка чыга һәм хәтта халыкларның мәнфәгатьләре дә мөһим түгел. Евразияче булулары да бик җиткән. Евразия дәүләте идеясе кешегә басым ясаучы, башка берни дә танымаучы, ул гына да түгел, кешедән корбан таләп итүче идеягә әверелә. Илаһилаштырылган Евразия дәүләтендә аерым кешегә генә түгел, бүтән идеологиягә дә, бүтән партиягә дә, бүтән фикергә дә урын юк. Бу тәгълиматтан бернәрсәгә дә юл куймый торган антикешелек исе килә.

Русиянең кыйтгалар арасында урта бер җирдә урнашуы, каннарның катнаш булуы, телдәге, традицияләрдәге, психологиядәге Көнчыгыш (нигездә төрки-татар) элементлары белән сугарылган мәдәнияте Русиянең үз цивилизациясе турында сөйләргә мөмкинлек бирә. Ул Европа һәм Азия цивилизациясеннән аерылып кына калмый, аның эчке бер тоташтыргыч үзәге дә бар. Әмма бу өстән караганда гына шулай тоела. Тирәнрәк анализ исә евразиячелек теориясендә үтеп чыга алмаслык каршылыкларны ачып бирә.

Евразия идеологиясенең үзәге — православие, янәсе, ул рухи тормышның бөтен төзелмәсен билгели. «Без Евразияне православие чиркәвенең һәм культураның аерым бер симфоник-шәхсән индивидуальләшүе дип аңлыйбыз»,— дип язалар евразиячеләр. Православиедә булмаган өлеш исә — «православиедә булуы мөмкин дөнья» гына. Урыс булмаган халыклар православиене үзенчәлекле кыйммәткә санап, аңа үзләреннән-үзләре тартылырга тиеш дип күзаллана. Тарих исә башкача күрсәтә.

Русиядә православие белән исламның үзара мөнәсәбәтләре мәсьәләсе евразиялеләр тарафыннан бөтенләй хәл ителми, бу очракта аларның Русия цивилизациясе оешу турындагы төп тезислары шик астында кала. Русиядә өстенлек итүче урыс православиесе цивилизациясенең барлыгы һичшиксез, әмма, имеш, славяннарны һәм төркиләрне, христианнарны һәм мөселманнарны берләштерүче Русия цивилизациясе булу турындагы тезис бәхәсле. Бу халыкларны бит цивилизация түгел, дәүләт бергә тотып тора.

Кайбер идеологлар, славяннар белән төркиләр арасында уртак чалымнар эзләп, әхлакый һәм социаль хәзинәләргә мөрәҗәгать итәләр. И.Василенко болай дип яза: «Славян һәм төрки телле халыкларга күмәк башлангычның индивидуальлектән өстенлеге хас. Бередә кешегә бәя беренче чиратта ыруг алдындагы бурычын үтәүгә карап бирелә. Мондый караш Европа менталитеты күрсәтмәләреннән шактый ерак тора, чөнки анда кеше иң элек индивидуаль шәхес буларак бәяләнә». Кайчандыр чыннан да шулай булган, әмма бу хәл ул заманда славяннарны һәм төркиләрне берләштерде микән? Чөнки ыруглар төрле булгач, бурыч та төрлечә аңланган бит. Бүген исә язмыш шаяруы шуннан гыйбарәт: урысларда да, татарларда да индивидуальлек көчәйде һәм ул аларны ныграк якынайта. XX гасыр җәмгыятьне байтак үзгәртте. Ыруг идеяләрен йөртүче крестьяннарның хәзерге көндә бернинди дә йогынтылары юк. Аңа каршы буларак шәһәр культурасы үсте, анда ачыктан-ачык индивидуализм һәм эшкуарлык куәте хөкем сөрә. Белем дәрәҗәсе аерым шәхеснең ролен арттырды. «Үзгәртеп коруның» төп сәбәпләреннән берсе — күмәклекнең коммунистик идеология элементы буларак яңа иҗтимагый юнәлешләр тәэсирендә җуела баруында, чөнки яңа юнәлешләр беренче планга шәхес һәм аның хокукларын куя. Урыслар белән татарларны традицион нормаларга караганда үсә баручы индивидуальлек һәм демократия хәзинәләре ныграк берләштерә. Этник чыгышларына бәйсез рәвештә тышкы дөньяга ачык, ирекле һәм белемле шәхесләр арасында уртаклык православиелеләр белән мөселманнарның йомык общиналары арасындагы уртаклыктан зуррак.

Аңлашыла ки, урыслар тәкъдим иткән иҗтимагый хәзинәләр Русиянең башка халыклары да кабул итәрлек булырга тиеш. «Ике фронтка» көрәшне һәм, димәк, бөтен дөньядан үз-үзеңне тәэмин итәрлек киңлекләрдә аерымлануны кабул итү татарлар өчен дә, башка халыклар өчен дә кыен булачак. Чынлыкта исә дөньяда төрки цивилизация яшәп килә. Татарлар, башкортлар, якутлар, чувашлар һәм башка халыклар —

аның аерылгысыз өлеше. Мөселман цивилизациясе бар. Татарлар бу гаять зур дөньяның бер өлеше генә дә, ислам динен тотучылар гына да түгел, татарлар — исламның иң төньяк терәге дә. Татарларны ниндидер бер Русия цивилизациясе кысаларына чикләү мөмкин түгел, чөнки бу аларның үсешенә киртә була һәм ахыр чиктә Русиянең үзен какшата. Татарлар өчен иҗтимагый системаның ачыклыгы, дөньяның төрле илләре белән турыдан-туры багланышлар, Көнчыгышка да, Көнбатышка да турыдан-туры чыга алу мөмкинлеге гаять әһәмиятле. Төрки һәм ислам факторлары — Русиянең ресурсы, алардан тиешенчә файдалана белергә генә кирәк.

Шул ук вакытта татарлар өчен дә, Татарстан өчен дә Русиядә кеше һәм халыклар хокуклары, ил белән идарә итүнең демократик принциплары, көч кулланмый торган дөньяны тану һәм башка шундый Европа кыйммәтләре таралу аеруча мөһим. Мондый кыйммәтләрдән башка татарларның этнос буларак яшәве дә шик астында кала, Татарстандагы татар-урыс балансы да җимерелергә мөмкин. Әгәр «Русия цивилизациясе» дөньядан читләшсә, ул Русиядәге күп халыкларның омтылышлары белән каршылыкка керәчәк. Әлбәттә, алар белән исәпләшмәскә дә мөмкин, аларның өлеше дә әллә ни түгел, 20% чамасы гына, әмма сәясәттә бүтән күрсәткечләргә таяну мәгъкульрәк. Чеченнар 1% тан да азрак, ә проблемалары гаять зур булып чыкты. Этносоциаль процессларны бәяләгәндә, гади арифметик алымнар сәяси хаталарга гына китерә.

Озак еллар буена Русия халыкларында үзәк буларак Мәскәүгә ышаныч кимеде. Үткәнне идеаллаштырып, кайбер публицистлар тәкрарлаган шикелле, гасырлар буена бергә яшәгән «халыклар арасында үзара аңлашу» хакында эйфориягә бирелергә ярамый. Бу мөнәсәбәтләр гел яхшы гына булмаган. Тарих урыс колонизациясенә һәм христианлаштыруга каршы күпсанлы баш күтәрүләрне дә, бүтән рәвешләрдә каршы чыгуларны да дәлилли. Билгеле, кайбер халыклар өчен Русиягә кушылу уңай хәл булган, алар Русияне «халыклар төрмәсе» дип кабул итмәгәннәр. Чыңгыз Айтматов язганча: «Рәхмәт язмышыбызга: ярый әле урыс халкы белән, Русия белән янәшә яшибез, язмышыбыз уртак, тарихыбыз уртак. Югыйсә бүген Үзәк Азия, Урта Азия нинди хәлдә булыр иде? Минемчә, һәрчак тискәре тарихи күренеш дип саналган колониализмга берьяклы гына бәя бирергә ярамый. Һәрнәрсәне үз исеме белән атыйк. Колониализм шуны аңлата: кешелек җәмгыятенең алгарак киткән өлеше цивилизацияләрдән читтәрәк торганнарны үзенә җәлеп итә (үз файдасын эзләп, билгеле) һәм аларны заман дәрәҗәсенә күтәрә. Кыргызстан белән дә нәкъ шулай булды». Үзәк Азиядә колонизация шактый тыныч, җирле халыкларның мәнфәгатьләрен исәпкә алып үткәрелде. Шул ук вакытта татарларны яисә Төньяк Кавказның күп кенә халыкларын Русиягә көчләп куштылар һәм әлеге халыклар моннан бернинди файда да күрмәде. Еш кына аларга бөтенләй бетү куркынычы янады.

Гади кешеләр үзара тату яшәп, уртак тел таба алдылар. Әмма тагын дәүләт тә бар бит әле, дәүләт, урыслар исеменнән эш йөртсә дә, еш кына чит халыкларга гына түгел, урысларга да яхшы мөнәсәбәттә булмады. «Цивилизация синтезы»ның нигезе буларак, халыклар арасында үзара аңлашуга ничек ирешергә, дәүләттән куркуны ничек җиңәргә, иң мөһиме Мәскәүнең илдә яшәүче халыкларга карата сәясәтен ни рәвешле үзгәртергә соң?

Уртак язмыш принцибы урынына халыкларның һәм мәдәниятләрнең тигезлеге, этникара һәм башка эчке сәяси проблемаларны хәл иткәндә көч кулланмау принцибын игълан итү мәгъкульрәк булыр иде. «Халыклар берлеген» ничектер башкача төзү мөмкин дип уйлау — беркатлылык ул. Дәүләт Думасының татарча латин графикасын тыюы Русиянең урыс булмаган халыклар белән уртак тел табудан хәзергә бик ерак икәнен күрсәтә. Шунысы да үзенчәлекле: бер генә евразияче дә, хәер, демократлар, либераллар кебек үк, татар халкының туган теле үсеше юлларын мөстәкыйль билгеләү хокукын яклап чыкмады.

С.Хантингтон күзлегеннән караганда, православие, ислам һәм буддизм — төрле цивилизацияләр, бергә, янәшә яшәүче, әмма бер-берсенә кушылмас дөньялар. Шуңа күрә, әгәр аның мантыйгына иярсәң, урыслар, татарлар, бурятлар, фин-угырлар, Кавказ халыклары бер үк дәүләттә, әмма төрле цивилизация дөньяларында яшиләр. «Цивилизацияләр бәрелеше» сугыш яисә конфликт белән генә тәмамланырга тиеш димәгән ләбаса. Халыклар тату яшәү турында үзара килешергә дә мөмкиннәр. Католиклар белән протестантлар арасындагы элеккеге мөнәсәбәтләрнең никадәр канлы булуын искә төшерик. Бүген алар либераль идеяләргә корылган бердәм Европа цивилизациясенең нигезен тәшкил итәләр. Кайчакта бер үк дин тотучылар да үзара эчке сугышлардан сакланып кала алмыйлар. Цивилизация җәһәтеннән мондый караш халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрнең күптөрлелеген аңлатып бирмәсә дә, җәмгыятьнең кайбер төп нигезләре турында уйланырга мәҗбүр итә, аларны күрмәмешкә салышу бөтенләй үк зарарсыз түгел.

Русия цивилизациясе юк, бер дәүләттә үзара тыныч яшәүче православие, мөселман һәм башка культуралар бар, алар бердәм цивилизация тәшкил итмиләр.

Бүгенге евразиячелек идеологиясенең конфликтлар тудыруы бик мөмкин, чөнки ул, төрле халыклар һәм илләр өчен гомуми хәзинәләр тәкъдим итмичә генә, дәүләтне иске чикләрендә торгызу турында сөйли. Мондый очракта ул бары тик көч куллануга гына өметләнә ала. Чынлыкта евразиячеләрне урыс булмаган халыкларның яңарыш кичерүе һәм аларның башка илләр белән багланышлары борчый. Д.В.Драгунский

ачыктан-ачык яза: «Оренбург коридорына бәйле этносәяси проблемалар — Төньяк Казахстандагы, Башкортстандагы һәм Татарстандагы урыс һәм төрки халыклар статусы да; этносоциаль киштәләрне бүлешү дә; этник көндәшлекнең потенциаль зоналары да; миграция, шул исәптән башкортларны һәм татарларны үз республикаларына «кайтару» тенденциясе турындагы мәсьәлә дә; Оренбург өлкәсенең этнодемографик композициясе дә ул». Авторны славяннарның һәм төркиләрнең берләшүе борчымый, ул төркиләрнең көчәюеннән һәм бу халыкларның империя куып кертә алган кысалардан чыгуыннан курка. Урыс булмаган халыкларны киң дөньядан читләштерү өчен боларны тәкъдим итә: «Казахстан белән Идел буе төрки республикаларын кушылдырмаска кирәк, моның Русияне Көнчыгыштан аеруга китерүе мөмкин». Авторның сәер мантыйгы буенча татарларны Көнчыгыштан аерып кую, «Оренбург коридорын» ныгыту Русия белән Көнчыгыш арасындагы багланышларга күбрәк ярдәм итәчәк. Әлбәттә, бу — мәгънәсезлек, әмма язмышлар уртаклыгы турындагы сөйләнүләргә караганда, әлеге сүзләрдә хакыйкать күбрәк. Һәм бу, кызганыч ки, теоретик фикер йөртүләр генә түгел.

Н.Бердяев болай дип язган: «Евразиячелектә.... зарарлы һәм агулы элементлар бар һәм аларга каршы торырга кирәк. Урысларның күп кенә иске гөнаһлары евразиячелек идеясенә бик күпертелеп күчерелгән. Евразиячеләр бөтендөнья кризисын сизәләр. Әмма алар бүген без катнашучы яңа тарихның ахыры булып эллиннар дәверенә охшаш яңа универсаль дәвер барлыкка килүен аңламыйлар. Хәзерге вакытта милләтләрнең үз эчләренә йомылып яшәү заманнары тәмамлана. Барлык милли организмнар дөнья әйләнешенә һәм дөнья киңлекләренә тартып кертелгән. Көнчыгыш һәм Көнбатыш культура типлары бер-берсенә үтеп керә. Көнчыгыш автаркиясе тәмамланган кебек үк, Көнбатыш автаркиясе дә тәмамлана». 20 нче елларда гадел булган нәрсә бүген дә — алга киткән коммуникацияләр, ачык чикләр һәм глобальләшү заманында — аеруча көнүзәк. Евразиячелек төрле халыклар һәм культуралар өчен берләштерү идеясе була алмый, шуңа күрә демократия шартларында аның киләчәге юк.

Трубецкой, Савицкий, Вернадский Русиянең рәсми тарихтан бөтенләй аермалы тарихын аңлатып бирделәр. Алар Русия дәүләтчелегенең тирән катламнарын ачтылар. Шул ук вакытта аларның Туран киңлекләре үз-үзен тәэмин итә ала дигән нәтиҗәләре шикле. Алар үзләре үк күп мәртәбәләр һәм үтемле итеп язган Чыңгыз хан рухы теләсә нинди аерымлануга ят, нәкъ менә шушы рух Көнчыгышны Көнбатышка каршы куймый, киресенчә, аларны берләштерә. Хәзерге заманның бу үзенчәлеген Н.Бердяев бик дөрес тотып алган һәм болай дип күрәзәлек кылган: «Минем тарафтан дөньяга социалистик караштан космик карашка күчү дип тасвирланган рухи борылыш саф сәяси нәтиҗәләргә һәм чагылышларга ия булачак. Социаль-сәяси төбәклек гадәте җиңеләчәк. Социаль һәм сәяси аң алдына дөнья киңлекләре, бөтен Җир шарын биләү һәм аңа идарә итү проблемасы, Көнчыгыш белән Көнбатышның якынаюы, барлык типлар һәм мәдәниятләр очрашуы, кешелекне бөтен расаларның көрәше, үзара хезмәттәшлеге һәм аралашуы аша берләштерү проблемалары килеп басачак. Аларның тормышчан куелышы сәясәтне тагын да галәмирәк, ачыграк итә, тарихи процессның үзенең галәми киңлекләренискә төшерә». Н.Бердяев глобальләшү процессларын бик күпкә алдан тотып алган.

Үзен Көнбатышка һәм Көнчыгышка каршы кую идеологиясе Русияне тарихи тупикка кертә. Күпләр Русия үзендә Көнбатыш белән Көнчыгышны тоташтыра дип күзаллый, чөнки бу ил бер үк вакытта Европада да, Азиядә дә урнашкан. Әмма бу географик алдавыч кына. Культура географиягә тәңгәл түгел. Русия Көнчыгыштан китте, ә Көнбатышка барып җитмәде. Православие цивилизациясе буларак аның Көнчыгыш түгеллеге анык, ә тормыш нормалары, менталитеты буенча аны Көнбатыш дип тә атап булмый. Ул бернәрсәне дә тоташтырмый, ул юллар чатында тора.

Евразия төшенчәсе эчтәлеге буенча шактый томанлы. Күчмә культура буларак Дала цивилизациясе булган. Әмма Бөек Дала күптән юк инде. Элеккеге Төрки каганлыклар һәм Дәшти Кыпчак биләмәләрендә көн итүче утрак, игенчелек, сәнәгать, шәһәр культурасы бар. Ләкин бу бөтенләй бүтән цивилизация.

Евразияне славян-төрки симбиозы дип шәрехләргә мөмкин. Бу очракта аның даирәсенә Төркияне дә кертергә кирәк, әмма классик евразиячеләр моны хәтта тикшермәгәннәр дә, алар элеккеге Монгол империясе территориясен генә күз алдында тотканнар. Бүгенге евразиячеләр дә Монголияне Евразиягә кертергә әзер, гәрчә Монголия төрки цивилизация өлеше булмаса да. Әмма алар Төркияне берничек тә Евразия тәшкилиятендә күзалламыйлар. Евразиянең гамәлдәге билгеләмәләрендә мәдәни дәлилләр мантыйгына урын юк.

Хәзерге Русия территориясе борынгы заманнардан ук Иран культурасы йогынтысын тоеп яшәгән. Петр заманында фарсы сугышлары Көнчыгыш сәясәттәге төп вакыйгалар булып торган. Иран телле илләрне төшереп калдыру сәер һәм гайре табигый булыр иде, әмма евразиячеләр Таҗикстанны Туран төшенчәсенә кертәләр, ә Иран белән Әфганстанны төшереп калдыралар. Иран белән Әфганстан исә хулагучылар чорында Монгол империясенең бер өлешен тәшкил иткән.

Евразия территориясен кайсыбер илләрне төшереп калдыру юлы белән билгеләп карарга була. Мәсәлән, Кытай борын-борыннан Дала белән сугышкан һәм шул җәһәттән Евразиягә каршы торган. Һиндстан территориаль яктан ерак, Евразия белән бәйләнешләре бик аз булган. Гарәп илләре исә Даладан һәм урман-даладан Иран илләре һәм төрки илләр белән бүленгән, гәрчә ислам Евразия кыяфәтенә көчле йогынты ясаса да. Әгәр Кытай, Һиндстан, Пакистан һәм гарәп илләрен төшереп калдырсаң, тарих буенча һәрчак тыгыз бәйләнештә торган үзенә бертөрле даирә барлыкка килә. Әлбәттә, нәрсәнедер төшереп калдыру уңай хәл түгел, ләкин ниндидер аныклык барлыкка килә.

Мәсьәлә Евразиянең төньяк һәм көньяк чикләрен билгеләү белән генә хәл ителми, чөнки көнбатыш чикләр ачыкланмый кала. Классик евразиячеләр бу теорияне герман-роман дөньясы белән каршылыкка корганнар, хәзерге евразиячеләр хәтта атлантчыларны да, ягъни, туры гына әйткәндә, НАТО әгъзаларының барысын да кертәләр. Европа чикләре СССР барында һәм Европа Берлеге югында төгәл билгеле иде. Соңгы елларда Европа үзенең хәрәкәтчәнлеген күрсәтте, Европа Берлегенә яңадан-яңа илләр керә башлады, һәм аның чикләре Көнчыгышка таба бик тиз җәелеп бара. Европа, үзенең асылы турында уйланып калгандай, берникадәр вакытка ислам дөньясы чикләрендә туктап калды. Әмма Европа өчен иң мөһиме дини хәзинәләр түгел, либераль хәзинәләр, шуңа күрә аның Көнчыгышка таба хәрәкәт итүе котылгысыз. Төркия — Көнбатыш тарафдары һәм ул үзен Евразия кыйтгасының бер өлеше дип тоймый. Шуңа күрә Евразия территориясенең билгеләмәсе гаять субъектив мәсьәлә булып кала.

Соңгы гасырларда Русия үзен Азия державасы кебек түгел, күбесенчә Европа державасы кебек тотты. Династия никахлары, Европадагы сугышлар, сәяси берлекләр моны тагын бер кат раслап тора. Европа исә XVIII йөздән башлап үзенең көнчыгыш чикләре итеп Уралны санады, шул рәвешчә ул Русияне дә Европа державасы дип таныды. Моңа патша Русиясенең колониаль империя статусы да ярдәм итте, анда үзәк Русия үзенең Себердәге, Ерак Көнчыгыштагы, Урта Азиядәге һәм Кавказ аръягындагы биләмәләреннән аерылып торган.

Октябрь революциясе иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә генә түгел, Русиянең элеккеге эчке колонияләрендә дә күп нәрсәләрне үзгәртте. Русия ике кыйтгада урнашкан республикалар Союзына әверелде. Европа илләре белән идеяләр җәһәтеннән аерымлану башланды һәм бу Көнбатыш белән Көнчыгыш арасында каршылык китереп чыгарды. «...Русиядәге Гражданнар сугышы, Советлар Русиясендәге көнбатыш интервенция, әмма иң элек эшчеләр хәрәкәтенең Көнбатышта ныгыган социаль-демократик юнәлешкә һәм Көнчыгышта хакимияткә килгән коммунистик юнәлешкә кан коеп таркалуы, башында Ленин белән Троцкий торган дәүләт терроры һәм диктаторлык режимы урнаштыру кебек үк, Русиянең Көнбатышныкы һәм Европаныкы булуына Көнбатышта кабат шик тудырды»,— дип яза Эгберт Ян. Көнбатыш чик социалистик һәм капиталистик лагерьларның каршылыгы белән билгеләнә иде. Хәер, социалистик лагерь да бертөрле түгел иде. Күп илләр үзләрен Европага кертәләр һәм Көнбатышта аларны Көнчыгыш Европа дип саныйлар иде. Хәтта СССРның үзендә дә Балтыйк буе республикаларындагы халыклар үзләрен һәрвакыт Европага кертәләр иде.

Вазгыять исә үзгәртеп кору заманнарында, Горбачев белән Ельцин Көнбатышка таба юнәлеш алгач кына үзгәрә башлады, һәм моны Европа шатланып каршы алды. СССР таркалу Русияне тагын да европачарак державага әйләндерер сыман иде, чөнки бөтен Үзәк Азия һәм Кавказ аръягы «китеп барды». Русияне Европа Советына алу әһәмиятле факт иде. Әмма икътисад реформаларының уңышсызлыгы халык арасында Көнбатышка каршы карашлар уятты.

1917 елгы революциягә кадәр Евразиядә иң төп фактор — православие экспансиясе булган, урыс солдатлары һәм православие миссионерлары барып җиткән җир Евразиягә әверелә барган. Бу территориягә, чыннан да, Монгол империясенең төп өлеше кергән. Совет чорында Евразиянең мәгънәви элементы булып социализм торды. Дошманнар һәм дуслар идеологик билгеләрдән чыгып билгеләнде. Бүген исә тегесе дә, бусы да юкка чыкты. Идея һәм дөньяга караш кебек тоташтыргычлар да, оборонада уртак бурычлар да юк һәм хәтта сәүдә дә тиешенчә үсә алмый. Советлардан соң урыс телен онытмаган гаять көпшәк киңлекләр калды, чик буйларында гадиләштерелгән режим сакланды һәм эшче көчләр миграциясе бар, калган даирәләрдә һәрбер ил исән калуның Евразиячә түгел, үзенчә стратегиясен эшли.

Урыс идеологиясе һәрвакыт мессианчылык, тоталитар, авторитар идеология иде. Русия аңы нинди дә булса арадаш, көндәлек нәрсәләрне кабул итә алмый. Мессианлык традицияләре Русияле җанны аздырган һәм хәзер бу җан гади гамәлләр, гадәти хезмәт белән шөгыльләнергә, тиенен тиенгә җыеп байлык тупларга, чүп-чарны себереп түгеп, территориясен төзекләндерергә теләми. Аңа могҗиза кирәк, аңа дөньяны гадәти булмаган берәр нәрсә белән шаккатырырга кирәк яисә берни дә кирәкми — Көнчыгыш та, Көнбатыш та. Мессианлыкка либераль аң каршы тормаган. Мессианлык традицияләре бөтен җәмгыятькә үтеп кергән империячел инстинкт рәвешендә теркәлеп калган.

XX йөздә империяләр, динозаврлар кебек, искелек калдыгына әверелделәр. Алексис де Токвиль әйтмешли, «Кешеләрнең тормыш муллыгына һәм ирегенә олы империяләр хәтле комачаулаучы нәрсә юк». Дөньяның төп юнәлешләре демократиягә, базар мөнәсәбәтләренә, кеше һәм халыклар хокукларын яклауга юл ачты. Русия, үз яшәешен һәм сәясәтен мифларга яисә бөек держава турындагы истәлекләргә корып, каршы торуын дәвам итә, әмма бу күбрәк үлем газабын хәтерләтә. Русия империячел традицияләрне саклый алмый, ә дәүләт һәм икътисадка идарә итүнең яңа формаларына күчәргә, бүтән иҗтимагый хәзинәләрне кабул итәргә аның сәяси ихтыяры җитми. Сәяси мәкерләрнең барлык коллизияләре һәм борылышлары империячел амбицияләр белән аларны тормышка ашыру өчен кирәкле ресурслар булмау арасындагы; илне яңарту ниятләре белән моңа кирәкле ихтыяр көче җитмәү арасындагы каршылыклардан килеп чыга.

Лорд Актон әйткәнчә, «иреклеләр җәмгыяте озак, күпкырлы һәм газаплы тәҗрибә нәтиҗәсендә генә барлыкка килергә мөмкин». Әмма Русиянең сәяси элитасы бернәрсәдән дә сабак ала белми, сәяси тетрәнүләрдән соң Европа илләрендәге кебек реформалар башланмый. Державачылык культурасының искелеген, башбаштаклыкны җиңеп чыгу зарурлыгын аңлау юк. Тарихны җиңеп чыгу — империячел үткәннән катгый һәм тайпылышсыз төстә баш тарту дигән сүз ул. Империя нигезенә кадәр җимерелергә һәм барлык халыкларның да, барлык диннәрнең дә, барлык территорияләрнең дә мәнфәгатьләрен тигез кайгыртучы дәүләт төзелергә тиеш. Русия элитасы бу мәсьәләне хәл итә алмый, күрәсең. Башкала үзәкләштерү чире йоктырган, аңа халык тормышы кызыклы түгел, ул төбәкләрне аңламый, ә төбәкләр башкаланы аңламый, һәм барысы бергә бөек державачылыкка — илне шушы кризис хәленә төшергән державачылыкка өметләнә. Империячел инстинкт бик күп карарларны билгели. Татарлар, культура символларының берсе булган кириллицадан баш тартып, урысларның мин-минлегенә тиделәр. Бу исә культураның зәгыйфьлеген аңлата, әмма урыслар моны танырга теләмиләр һәм аның үзҗитешлеген күрсәтүче теләсә нинди символга ябышалар. Революциягә кадәр Толстой әсәрләре татарларның гарәп графикасында басылган. Һәм бу хәл татарлардан башка берәүгә дә кагылмаган.

Бөтен культураның үзәкләшүе — илнең артта калуы билгесе. Артта калган җәмгыятьнең генә бөтен культурасы башкалада туплана. Төбәкләрнең хакыйкать тупланган урын дип Мәскәүгә генә карап көн итүе — искечә фикерләү билгесе. Русия шул рәвешчә кушылуы мөмкин булмаган нәрсәләрне — фикер ягыннан артта калган башкаланы архаик төбәкләр белән кушарга тырышып гомер итә. Шул ук вакытта «халык культурасы» Көнбатыш «китч» кыяфәтенә кереп бара. Ул хәзер дискотекаларда яши. Сирәк-мирәк зыялылар җыела торган кайбер мәдәният утраучыклары бар әле барын. Инерция буенча кала бирәме алар яисә башка сәбәптәнме... Башка урыннарны казино, төнге клублар һәм ресторан мәҗлесләре биләп алган.

Урыс мәдәнияте кризисы — Русиянең XIX һәм XX гасырлардагы бөек казанышларына йөз тоткан татар мәдәнияте кризисы да ул. Безнең халыкның аңы һәрчак икенчел булды, ул һәрчак нинди дер башка — ислам, гарәп-иран, урыс үрнәкләренә ияреп йөрде, әмма үз аңын үстерми калды. Ул тарихтан читтә яшәде. Бу аң Русия империясен, Куликово сугышының дөрес шәрехләнмәвен өнәмәде, 1552 елгы вакыйгалар тирәсендә тулганды, әмма асылда тарихи була алмады. Татар үзаңы Алтын Урда һәм Казан ханлыгы җимерелүдән сабак ала алмады. Тарихтагы каһарманлыкны курыкмыйча каһарманлык дип атарга кирәк, хәтта бөтен дөньяның традицион тарих фәнендә ул варварлык дип күрсәтелсә дә. Дөреслекнең күзенә карарлык, үз тарихыңа тәнкыйди бәя бирерлек, татар дәүләтләренең җимерелү сәбәпләрен күрерлек, үз ялгышларыңны һәм рухың зәгыйфьлеген танырлык, үзеңнең кимсетелгән милли тормышыңа аклау эзләмәслек батырлык кирәк. Рухыңның артта калганлыгын һәм кол булуын аклау өчен дәлилләр юк ул.

Дәрдмәнд шигъриятендә «гарип моң» темасы бар. Бу — ватаныннан аерылган дәрвиш яисә ата-бабалар җиренә әйләнеп кайту темасы. Таң белән бергә гарипләнгән моң туа һәм җил аны туган ягына алып китә. Бу сәер тема мескен татар рухының чын халәтен чагылдыра. Җан гарип, шуңа да моң гарип, чөнки тормыш үзе имгәтелгән. Шагыйрьнең гарип татар җаны турындагы әлеге сүзләрен бүген дә кабатларга мөмкин. Татарлар гомумрусия культурасы (антикультура дисәң дә ярый) йогынтысы астында үз йөзләрен югалтканнар. Кеше үзен биш елдан металл өеменә әвереләчәк кыйбатлы машина алып күрсәтергә тырыша, өч катлы коттедж сала, анда яшәр кешесе юк, банкетларга, күңел ачуга бер олау акча түгә, ә китаплар чыгарырга яисә университетларга ярдәм итәргә акча табылмый. Бу — җиңел табыш артыннан куып, мал-мөлкәт җыярга атлыгып, алтын-көмешкә табынып гарипләнгән җаннар.

Татарның фикерләү рәвеше күбесенчә этник яктан сакланып калу ихтыяҗы белән билгеләнә. Бу — тәнкыйди фикерләү, әмма тәнкыйть үзенә таба түгел, тышкы шартларга юнәлтелгән. Бу фикерләү иҗади түгел, бары үз-үзеңне яклау гына. Ул йә традицияләрне саклап калу шигаре астында этник асылны «катырып куюга», йә үз халыкларын җәберләүче «ил мәнфәгатьләре белән» генә яшәүгә юнәлдерелгән, монысы гаделсез хакимияткә каурысыз буйсынуны аңлата. Төбәклек шуннан гыйбарәт ки: татар фикере башкаларны тәнкыйтьли, шуңа күрә ул кол фикерләве булып тора, чөнки ирекле фикер үз-үзен тәнкыйть итә, ирекле фикергә үзтәнкыйть хас. Татарларда мөстәкыйль идеяләр үз-үзләренә тәнкыйди карый башлагач кына ки-

леп чыгачак. Менә шул чакта рух бәйсезлеге дә барлыкка килер. Чын миллилек һәрвакыт иҗади, ул катып калырга тиеш түгел. Милләтне саклап калуны искелекне катырып кую белән бутарга ярамый. Җирсү рухны көчәйтми, ә катып калу — бер урында таптану ул. Резервациядән чыгар юл юк, ул — тупикта. Индеецлар романтикасын басып алучылар уйлап тапкан, алар тарихи гөнаһларын юар өчен үзләренә резервацияләр рәвешендә индульгенция уйлап чыгарганнар.

Рух төпкелләре тискәредән уңай фикерләүгә күчкәндә, әзер доктриналардан котыла белгәндә генә ачыла. Тарихны доктриначылык һәм үз мөмкинлекләрен файдаланып бетергән этник сюжетларны катырып кую белән көчләргә ярамый. Ирекле һәм иҗади рух доктриналардан да, партияләр белән дәүләт мәнфәгатьләре көрәшеннән дә, акча белән хакимияттән дә өстен. Башларын хәзерге пропаганда чуалткан беркатлы кешеләр генә бөтен нәрсә акчага һәм хакимияткә корылган дип саный, чынлыкта исә бөтен нәрсә рух халәтенә бәйле.

Тарихны җиңеп чыгу — үсеш юлын Көнбатыш файдасына бору ул, чөнки ирек идеясе нәкъ анда үсеш алган, димәк ки, тарих юнәлешен дә Көнбатышның фикер ияләре билгели. Бу юлны сайлау кулланучылар җәмгыятен һәм либеральләшүгә ияреп йөрүче бөтен тискәре күренешләрне үзеңә күчереп кую дигән сүз түгел, әлбәттә. Көнбатышның бу ягы Русиягә күчерелгән инде һәм, ни кызганыч, гротеск рәвешендә күчерелгән. Көнбатышчылык Петр I кебек бөтенесен тоташтан күчереп куюдан гыйбарәт түгел, аның мәгънәсе мөстәкыйль фикерләү булдыруда, бөтендөнья тәҗрибәсен үзләштерә белүдә. Бүгенге көндә либераль җәмгыятьне алга киткән илләрнең бик күп тискәре күренешләре белән тәңгәлләштерәләр. Фахишәлекне, наркоманияне, җинаятьчелекне либерализм тудырмый. Мондый күренешләрнең сәбәбе — лаеклы оппозиция булмау. Либерализмда бөтен нәрсә дә рөхсәт ителә һәм бар нәрсәгә дә тигез караш чиксез була дип аңлау дөрес түгел. Наркоманиягә, җинаятьчелеккә һәм башкаларга түзеп тору яки түзмәү — һәркемнең шәхси хокукы. Теге яки бу карарны җәмгыять үзе сайлап алырга мөмкин. Либерализм тормышның тискәре якларына тәнкыйди карашны аңлата, шул ук вакытта ул демократиягә дә тәнкыйди карый, әмма аны инкарь итү күзлегеннән түгел, киләчәктә аны үстерү максатыннан.

Демократия карарлар кабул итүнең максатларга бәйсез рәвешле үзенчәлекле тәртибен билгели. Әгәр әлеге тәртипнең үзен гаделлек һәм иҗтимагый әхлак белән чагыштырмыйча гына абсолютлаштырсаң, «механик күпчелек» диктатурасы килеп чыгарга мөмкин. Демократияне бозу исә күпчелек ни теләсә шуны эшләргә хокуклы, күпчелекнең карарында гына хакыйкать һәм гаделлек була ала дигәнгә ышанудан килеп чыга. Күпчелек хуплаган теләсә нинди гамәлне гадел дип таныган мизгелдән гаделлек концепциясе үз мәгънәсен югалта. Гаделлек күпчелек ихтыярына тәңгәл түгел. «Әгәр демократия күпчелекнең чикләнмәгән ихтыярын аңлатса, мин демократ түгел, мондый идарәне исә зарарлы, ә ерак киләчәктә яшәүгә сәләтсез дип саныйм»,— дип язган Ф.Хайек. Күпчелекнең чикләнмәгән ихтыяры — диктатурага турыдан-туры юл ул. Чын ирекле кешеләрнең ирекле җәмгыятендә теләсә нинди хакимият кешеләрне берләштерә торган уртак күзаллаулар белән чикләнә. Кушма Штатлар оешып кына килгән заманнарда ук америкалылар шуны аңлаганнар: куәтле парламентта шәхес өчен үлем куркынычы яшеренеп ята, чөнки парламент иреге башбаштаклыкка әверелә. Ике юлның берсен сайларга: йә ирекле парламент, йә ирекле халык. «Шәхес ирегең саклап калу өчен теләсә нинди хакимиятне — хәтта демократик парламентны да — озак вакытка каралган һәм халык хуплаган принциплар белән чикләп куярга кирәк». Күпчелекнең азчылыкны нәрсәгәдер мәҗбүр итү хокукы катгый кагыйдәләр белән чикләнгән булырга тиеш. «Идарә итүнең теләсә нинди рәвешендә түбәнлек һәм көч, ялагайлык һәм хакимлек янәшә урнашачак, кешеләрне эчтән таркалудан саклап калу юлы бер генә: җәмгыятьтә беркем дә хакимияткә тулаем ия булырга тиеш түгел», — дип язган Алексис де Токвиль. Гаделлек идеяләре белән тулыландырылган демократия генә ирекле җәмгыять барлыкка килүгә ярдәм итәчәк.

Либерализмга альтернатива юк, шуңа күрә дә Русия Европа белән интеграцияләшүгә йөз тотарга тиеш. Европа чикләре либеральләшүнең тулаемлыгы белән билгеләнәчәк һәм Европа үз тәшкилиятенә яңаданяңа илләр кабул итәчәк, либерализм идеясенең универсальлеге аны төзүгә нигез булачак һәм шуңа күрә дә ул теге яисә бу илне өстен куймаячак.

Урыс булмаган халыклар империячел традицияләрне җиңеп чыгу өчен тәнкыйтьтән гайре нинди дә булса гамәли өлеш кертә алаларммы соң? Һичшиксез кертә алалар. Аларның киләчәге демократия урнашуга турыдан-туры бәйле. Татарларның мәдәни үсеш чорлары Русиянең хөрриятле заманнарына туры килә: 1905 ел, 1917—1929 еллар, «үзгәртеп кору» чоры. Демократия һәм федерализм ягында тору — үзеңнең һәм илеңнең киләчәге турында уйлау дигән сүз ул.

Төркия Оттоман империясеннән республикага әверелгән чорда, эмигрант татарлар империячел рух урынына милли төрки рух керткәннәр. Йосыф Акчура җитәкләгән «Төрк урду» журналы империячел булмаган карашларның иң төп идеологик көчәйткече ролен үтәгән. Йосыф Акчураның Төркия Республикасына нигез салучы Кемаль Ататөрекнең сәяси киңәшчесе булуы очраклы хәл түгел. Әдәбиятта хәтта «Төрек

Республикасының татар моделе» дигән төшенчә дә бар. Бу тәҗрибә бүген Русиядә дә кабатланырга мөмкин, гәрчә бүген максат бүтәнчәрәк билгеләнсә дә. Империягә каршы позиция иң элек федерализмны һәм республикалар статусын яклауда чагыла. Әгәр кайбер параллельләр уздырсак, Русия федерализмының татар моделе кирәк һәм барлык демократик чагылышларны яклау зарур. Русиянең бәласе шунда ки: ул Көнбатыш технологияләрен, белемен һәм тауарларын кабул итәргә әзер, ләкин прогресска китерерлек иҗтимагый институтлардан йөз чөерә. Русиядә демократия ярым-йорты, ул —«идарә ителүче демократия». Мондый сүзтезмә үзеннән-үзе мәгънәсез. Федерализм «хакимият вертикале» белән яраша, гәрчә билгеләмәсе белән үк аңа бөтенләй якын килмәсә дә. Судлар төбәкләрне, халыкларны һәм кешенең үзен яклыйсы урынга үзәкне яклауга эшли. Үзидарәне аңлатуы да кыен, чөнки аның хәерчелектән, хокуксызлыктан һәм акчасызлыктан гайре бернинди дә мәгънәсе юк. Русияне, ниһаять, акыл белән аңлап, аршынлап үлчәр вакыт җитте, югыйсә аның таркалу процессын кире кайтару мөмкин булмаячак.

Урыс булмаган халыклар өчен тарихны җиңеп чыгу — дөньяга карашны котылгысыз рәвештә чикләүче йомык милли тирәлектән чыгу ул. Урыс булмаганнар арасында күренекле шәхесләрнең бик сирәге генә милли тормышта яши, үз халкының проблемаларына чумган очракта аларның дөнья киңлегенә чыга алуы икеле. Чөнки аларның фикерләве чикләнгән була. Бу урыс булмаган халыкларның гаебе түгел, киресенчә — бәласе. Бүген исә дөньяда үзара бәйләнешләр арта бара һәм бу фактны аңлау бик мөһим. Өстәвенә ассимиляциягә этносның иң гыйлемле өлеше эләгә, ягъни урыслашу халык саны кимүгә генә түгел, халык генофондының сыйфаты начарлануга да китерә.

Яңа идеяләр эшләп чыгару, алтын-көмешкә табынуны җиңеп чыгу урысларга караганда урыс булмаганнар өчен мөһимрәк. Алтын-көмеш культы ватанпәрвәрлеге чамалы булган бик аз кешеләрне генә баета, ә яхшы идеяләр исә һәм рухи, һәм матди яктан бөтен халыкны баета. Яңарган рух халыкны һәм илне дә яңарта. Моны акча башкарып чыга алмый. Демократия идеяләр тудыру мөмкинлеген тәэмин итсә дә, идеяләр урынына үзе кереп утыра алмый.

Совет чорыннан исә илдә кулланылыш тапмаган техник белемнәр һәм үз-үзеңне тотуның гаять күп стереотиплары калды: үз проблемаңны дәүләт җилкәсенә салу, законлылыкны алмаштыручы башбаштаклык, мөлкәткә кимсетүле караш, йорт-җирнең тәртипсезлеге, хезмәт күнекмәләрен югалту һәм башкалар. Шуларга наркомания һәм фахишәлек килеп өстәлде. Демократия һәм базар мөнәсәбәтләре совет режимының тискәре күренешләрен җиңеп чыга алмадылар, шуларга килеп кушылдылар гына. Әхлак, тәрбия турында җәмгыять бөтенләй онытты. Дин әһелләре бу хакта кешеләрнең исенә төшерергә тырышалар тырышуын, тик үзләре дә еш кына бу әхлакны бозалар. Хайек болай дип язган: «Минем бернинди дә шигем юк: бер иҗтимагый төркемгә башкаларыннан өстенлек бирүче әхлакый традицияләр үткән заманда да прогрессны интеллектуалларга һәм аларның алдынгы проектларына караганда күбрәк тәэмин иткәннәр һәм бу киләчәктә дә шулай булачак. Эволюцияне без алдан күрә алган нәрсәләргә кайтарып калдыру прогрессны туктатырга маташуга тиң күренеш ул». Дөньяны байлар түгел, уңай кыйммәтләр хәрәкәткә китерә, еш кына әлеге кыйммәтләр ярлыларныкы булып чыга. Бай кеше болай уйлый: «Берәр нәрсә булса, сәдака бирәм дә, гөнаһларым кичерелә». Ярлы һәм урта катламнар әхлагы байлар әхлагыннан өстенрәк. Әхлакый кагыйдәләрне үтәүчеләр — җәмгыятьнең байларга караганда кирәклерәк әгъзалары. Җәмгыятьнең алга китешен идеалистлар билгели, чөнки аларда чын рух яши, ә идеал исә тормышның үзенә караганда кадерлерәк.

Теләр булсаң насыйп алмак сәгадәт кимиясыннан
Канәгать күшәсен тоткыл, кичеп дөнья сафасыннан.

Мөхәккыйкларның агзыннан ничә нәүбәт ишеттем мән:
Фәкъир ир сабры артыктыр ганиләрнең гатасыннан.

*Сәйф Сараи. XIV гасыр*

## «Татар Русе»

*Әй ханиям, ханиям!*
*Җир китәр дә ни калыр?*
*Җиреннән тайган ил калыр;*
*Ил китәр дә ни калыр?*
*Ил киткәндә йорт калыр,*
*Йорт китәр дә сөт калыр,*
*Ак күкрәктән сөт имгән*
*Сүзе татлы тел калыр.*
*Тел китәр дә ни калыр?*

*Язганнан язган хат калыр;*
*Баш китәр дә ни калыр?*
*Буыннан буын чабылса,*
*Ул чагында ни калыр?*
*Йорт урынында яу калыр?*
*Ялгыз башы каңгырап,*
*Куйдай булып маңгырап,*
*Чүл далада тинтерәп,*
*Дуадактай хан калыр.*

«Идегәй». XV гасыр

Татарлар өчен Русия чит территория түгел, аннан аерым тору яки киртә кую хаҗәте юк. Бу киңлекләрдә төрки-татар цивилизациясе мең елдан артык яшәп килә. Русия эчендә баштан ук ике дөнья, дөньяга ике төрле караш, ике мәдәният даирәсе яши: урыс-православие һәм төрки-ислам, алар бер-берсенә янәшә, бер киңлектә яши алып та, бер-берсе белән аз аралашалар.

«Татар Русе» дигән сүзтезмә мантыйкка каршы төсмердә, иҗтимагый тәкәбберлек сыман яңгырый. Күп гасырлар буена урыс аңында кайбер штамплары барлыкка килгән: «урыс гаярьлеге», «урыс каены», «урыс басуы», «урыс игелеге һәм күңел киңлеге», «Волга-анабыз — бөек урыс елгасы», «Изге Русь» һәм башкалар. Хәтта «Киң дала» дигән гыйбарә дә саф урыс символы буларак кабул ителә. «Далачы» — кыргый һәм йөгәнсез күчмә кеше булса да, Дала үзе урысныкы, иркен һәм иксез-чиксез. Иҗтимагый аңга татарныкы дигән һәрнәрсәне катгый кабул итмәү ясалма рәвештә кертелгән, бу хәл шушы гыйбарәләрдә «урыс» сыйфатын «татар» сыйфатына алмаштырсаң, ап-ачык күренә башлый: «татар гаярьлеге», «татар игелеге», «Идел — бөек татар елгасы», «Татар Русе». Әллә аң үзе, әллә аңның үзебез аңламаган төпкелләре каршы килә: рәхимсезлек, комсызлык, хәйләкәрлек кенә татарныкы булырга тиеш, әмма һич тә игелек түгел. Нәкъ менә шулай тәрбияләделәр. Татар телендә бу сүзләр, әлбәттә, бөтенләй башкача яңгырый. Гаярьлек, игелек, күңел киңлеге татар халкының холкына ярашып тора. Чыннан да, ир-егетне ничек күз алдына китереп була? Әлбәттә, гаярь итеп: ул дала буйлап атта җилдерә, озын, моңлы көйләр суза. Сәер килеп чыга: татар егете гаярьлеккә гаярь, әмма «татар гаярьлеге» — мәгънәсезлек, имеш. Шул ук Идел турында татар халкы үз дастаннарында күпме җырлар җырлаган, Идел-йорт дип атап, туган-үскән йорт символына әйләндергән. Идел, һичшиксез, «татар елгасы», урысларда ул шушы ук мәгънәдә күпкә соңрак пәйда була. Татарларда күз күргән һәрнәрсәгә «татар каены», «татар басуы» ише «татарныкы» дигән тамга салу гадәте юк. Ә менә Русияне татарныкы дип атап була.

«Татар Русе» үз законнары, үз мәнфәгатьләре, үз хәзинәләре булган үзенчәлекле, катлаулы һәм алга киткән аерым бер дөнья сыйфатында яшәп килә. Күп кенә Русиялеләр өчен — билгесез кыйтга, билгесез цивилизация ул, чөнки аларның күзен татарларга карата алдан ук тискәре мөнәсәбәт пәрдәсе каплаган. Бик күпләр, теләпме — теләмичәме, аны күрмәмешкә салышалар. Саратов үз губернасының 200 еллыгын гына билгеләп үтте, алар тарихка тирәнрәк карарга курыктылар. Чөнки тарих төпкеленнән Алтын Урда шәһәре Үкәк (Үвәк) килеп чыгарга мөмкин иде, ә аңа 2003 елда 750 ел тулды. Волгоград Царицын (Сарацин) шәһәренең нигезенә корылган. Әстерхан үзенең 400 еллыгын билгеләп үтәргә җыена, ләкин аның борынгырак шәһәр икәнен һәм урта гасыр карталарында Хаҗи Тархан дип аталганын бөтен кеше белә. Ибне Батутта анда XIV гасырда барган һәм болай дип язып калдырган: «Бу шәһәрнең исеме төркиләрдәге хаҗи, изге урыннарга барып гыйбадәт кылучы, шушы якларга килеп төпләнгән изге кеше атамасыннан килеп чыккан. Солтан аңа бу җирне пошлина түләтмичә генә биргән (ягъни аны тархан иткән) һәм биредә башта авыл калкып чыккан, үсә-бара шәһәргә әверелгән».

«Татар Русе» әйләнә-тирәбездә дип кенә әйтү аз, аның тормышы кайнап тора. Елга бер тапкыр ул башкалар өчен сабантуй бәйрәме рәвешендә калкып чыга, әмма анда башка вакыйгалар да җитәрлек: сәяси, мәдәни вакыйгалар, гомуммилли бәйрәмнәр, идеологиядә, әдәбиятта, музыкада хәтта үз революцияләре дә булып ала. Урыс газеталары бу хакта язмыйлар.

Совет чоры татар дөньясына шактый зыян китерде: кайчандыр куәтле булган икътисади төзелмәләр юкка чыкты, мәгариф системасы бозылды, һәм наширлек эшчәнлеге бөтенләй диярлек бетерелде, шуның белән бергә Русиянең күп кенә шәһәрләрендә мәгълүм татар үзәкләре җимерелде. Бүген Казан татарның бердәнбер мәркәзе булып калды.

Петербург башкаламы, юкмы дигән мәсьәләне тикшерергә мөмкин, әлбәттә, ләкин без моңа бу шәһәрнең чын гомумдәүләт вазифаларын үтәү ягыннан түгел, тарихи яктан гына карый алабыз. Ә Казанны исә татар башкаласы буларак бер генә шәһәр дә алмаштыра алмый. Мәскәү моңа дәгъва кыла алмый, чөнки анда интеллектуаль көчләр җитми, анда чын татар мәктәбе дә юк, татар мәдәнияте белән шөгыльләнерлек югары уку йортлары яисә фәнни үзәкләр турында әйтеп торасы да юк. Гәрчә Мәскәүдә Казанга караганда

күбрәк татар яши. Мәскәү татар мәдәниятен кулланучы булырга мөмкин, әмма аны җитештерә алмый. Моннан тыш Мәскәү әле ислам үзәге дә була алмый. Екатерина II, Казанга каршы куеп, Уфаны мөселманнарның дини нәзарәте дип игълан итсә дә, Уфа да мондый үзәккә әйләнә алмый. Ислам дөньясының бөтен төзелмәсе табигый рәвештә Казанда ясала. Татарларның бөтен төп гомуми эшләре — Бөтендөнья татар конгрессы корылтайлары, җыр конкурслары һәм театр фестивальләре, иаширлек эшчәнлеге, видео- һәм аудиоязмалар чыгару, теле- һәм радиотапшырулар эшләү Татарстанда гамәлгә ашырыла. Нәкъ менә шуңа күрә дә «Татар Русе» кысаларында Казанның башкала булуы турында сөйләргә мөмкин.

Иҗтимагый тормышта дәүләтнеке булмаган оешмаларның роле арткannan-арта бара. Бу — глобаль күренеш. Дәүләт күп кенә вазифаларын иҗтимагый оешмаларга, дини берлекләргә, сәяси хәрәкәтләргә һәм трансмилли корпорацияләргә тапшыра. Соңгы елларда иҗтимагый берләшмәләр халыкара оешмаларда турыдан-туры катнашалар. Казанның татарлар башкаласы дигән рәсми булмаган статусы — заманча процессларга бик туры килеп торучы күренеш. Мәсәлән, Барселона бөтен дөньяга, мөгаен, Мадрид кадәр үк билгеле шәһәрдер, ә үзе рәсми төстә бары тик Каталония башкаласы гына. Татарның тар милли аңын җиңеп чыгу Русия дәрәҗәсенә һәм Каталония мисалында чит илләргә чыгарлык проектлар эзләүне аңлата.

Казанга «Татар Русе» башкаласы буларак нәрсә җитми соң? Күрәсең, башкала рухы җитми. Казанда кешеләрне берләштерерлек яңа идеяләр һәм Мәскәүдәге мөлкәт җыю, җиңел табыш артыннан куу рухына, анда-санда баш калкыткан империячел карашларга альтернатива булырга тиеш. Федерализмны һәм демократияне яклау, һичшиксез, гомумтатар эшчәнлегенең иң мөһим юнәлеше, әмма киләчәк үсеш түгел, үзүзеңне яклау ягыннан гына. Милли кысалардан чыгарлык яңа проектлары булган һөҗүмчән программа кирәк һәм совет чорыннан калган мирасны — төбәк аңын җиңеп чыгу зарур.

Татарлар — үз тарихларында берничә мәртәбә үлем белән яшәү арасында калган халык, шуңа күрә дә этник яшәешнең бар нәрсәдән дә кадерлерәк икәне аңнарына сеңгән. Ассимиляция дәвам итә, әмма халыкка тулаем куркыныч янамый инде. Бүтән сыйфатка — XXI гасырда конкуренциягә сәләтлелеккә күчү чоры җитеп килә. Бу үзгәрешне хакимият тә, акча да билгели алмый, ул рухи әверелешкә бәйле.

Урыслар һәрвакыт «Нәрсә эшләргә?» дигән сорауны тәкрарлыйлар. Татарларда ул бүтәнчәрәк яңгыраган: «Кемнән өйрәнергә?» Дәүләтчелеген җуйганнан соң үзенчәлекле, мөстәкыйль татар фикере бөтенләй юкка чыккан диярлек. Татар фикере гади идеягә — этник мәдәниятне саклауга кадәр тарайды һәм үз дәүләтен тергезү турындагы хыялга әйләнде, ул татарныкы булган бөтен нәрсәне идеаллаштырды. Татарларда урыслардагы шикелле «Град Божий» эзләү, Ходай-кеше турында фәлсәфә сөйләү һәм башкалар юк. Бәхетле киләчәк халыкны якларлык гадел дәүләткә бәйле. Гаделлек эзләү юлында татарлар казахлар яисә кыргызлар кебек «Ак патша»га өметләнмиләр. Бөтен өмет — үз көчеңә, һәм вазгыять бүген дә шундый ук.

XX гасыр башында «Кемнән өйрәнергә?» дигән сорауга татарлар, иң элек урыс мәдәниятен күзаллап, Европадан дип җавап биргәннәр. Алар Европаны бөек урыс мәдәнияте аша кабул иткәннәр. Революциягә кадәрге татар мәдәнияте, дини киртәләрне җиңеп, халык үсешенең дөньяви механизмнарын эшләгән, бу аның дәрәҗәсен кискен күтәргән. Татар мәдәнияте дөнья хәзинәләренә ачылган, ул бик хәрәкәтчән рәвештә бөтен яңаны үзенә сеңдерә барган, яңалыкларны үз тормышына кертеп кенә калмыйча, төрки дөньяга тараткан. Үзәк Азиядә төрки телләрдәге бөтен матбугатны һәм нәшриятны татарлар башлап җибәргән, мәдрәсәләрдә, мәктәпләрдә һәм университетларда мөгаллим булып күбесенчә татарлар эшләгән. Мәдәниятнең ачыклыгы бик зур өстенлеккә әверелгән, чөнки ул иң заманча белемнәрне үзләштерергә ярдәм иткән.

Революциягә кадәрге бәхәссез казанышларның тагын берсе — икътисади төзелмәләр үсеше. Татарлар үзләренең банк системасын булдыра алмый калганнар, ләкин сәүдә өлкәсе һәм сәнәгатьнең кайбер тармакларын инде үзләштергәннәр. Революциядән соң бу төзелмәләр буржуазия, кулак һәм интеллигенция сыйныфлары белән бергә юк ителгән. Бүген татарларның менталитетына баю, мөлкәт җыю рухы зур зыян салган. Совет чоры, саф милли әхлакны какшатып, шушы вазгыятьне әзерләп биргән. Шәхси мөлкәт җыяр өчен килеп туган шартлар милли кыйммәтләр белән тигезләнмәде. Татарларның күп катлы коттеджлар төзергә һәм иң кыйммәт машиналар алырга ташланулары рухның зәгыйфьлеген күрсәтә. Инстинктлар рухи башлангычтан өстенрәк булып чыкты. Имамнар кешеләрдә рухи башлангыч тәрбиялисе урынга үзләре дә шул ук юнәлештә киттеләр. Аларны һич тә дәрвиш дип атап булмый, алар ул кадәр үк ярлы түгелләр. Чынлыкта исә интеллигенция катламы да чамадан тыш юка булып чыкты, өстәвенә «үзгәртеп кору» шартларында бу катлам көтмәгәндә хәерчеләнде, һәм күп кенә зыялылар хәзер дә байлардан акча тамганын көтеп, очын очка ялгап кына яши. Язучыларның таяныч ноктасы юкка чыкты, һәм алар хәзер «фикер хакимнәре» түгел. Совет чоры — татарлар тарихында иң авыр заманнарның берсе, әмма шул чорда нәкъ менә язучылар һәм театр сәнгате татар мәдәниятен үз җилкәләрендә сөйрәп чыкты. Алар күренекле сәнгати казанышларны саклап кына калмадылар, яңаларын да тудырдылар. Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Фатих Кәрим, Сибгат Хәким, Әмирхан Еники, Муса Җәлил, Габдрахман Әпсәләмов, Туфан Миңнуллин һәм башкалар совет язучылары сыйфатында мәгълүм булсалар да, татар рухының чын

сакчыларына әйләнделәр, үз йөрәкләрендәге милли очкыннарны «үзгәртеп кору» заманнарына кадәр китереп җиткерделәр. Һәм кинәт кенә бушлык пәйда булды. Татар язучыларының саны елдан-ел арта бара, ә укырлык нәрсә юк. Моны татарга гына хас күренеш дип әйтеп булмый. Урыс әдәбиятында бу хәл бераз иртәрәк килеп туды. Типик пропагандадан читкәрәк китеп, яхшылап уйлап карасаң, зур исәп буенча Михаил Шолохов, Анна Ахматова һәм Александр Твардовскийдан соң Хәсән Туфан һәм Әмирхан Еники белән янәшә куярлык башка совет язучысын табуы кыен. Татарларга реклама ясамадылар, әлбәттә. Кече халыкларның шагыйрьләрен тәкъдим итү куркынычсызрак иде: Рәсүл Гамзатовны, Кайсын Кулиевны, Давыт Көгелтиневне яисә урысларны — Астафьевны, Михалковны, Евтушенконы, Вознесенскийны, Рождественскийны, Богуславскийны тәкъдим иттеләр. Урыс шигърияте һәм прозасы заманында мәшһүр булсалар да, дәверләрдә сакланырлык әһәмияткә ия түгелләр иде. Чын «фикер хакимнәре» — Чыңгыз Айтматов һәм Олжас Сөләйманов иде. Сөләймановны тыярга да тырышып карадылар, Айтматов исә цензура өчен чамадан тыш мөһим фигура иде, ул үз әсәрләрендә, Шолохов Гражданнар сугышы чорын чагылдырган кебек, совет чорын тулысынча гәүдәләндерде. Чыңгыз Айтматов совет режимының ахырда тоталитар стройны һәлакатькә китергән авыру ноктaларын күрә белде. Кызганыч ки, бүген андый шәхесләр юк. Язучы үз заманы сулышын тоеп яши. Ул әле үз дәвере тәмамлангач та яши бирә, тик бернәрсә дә иҗат итә алмый. Шолохов Гражданнар сугышы тәмамланганнан соң бер бөек әсәр дә язмаган һәм, гомумән, язудан туктаган да үзенең хуторы Вешенскийда яшәгән, балыкка йөргән. Олжас Сөләйманов филологик тикшеренүләргә кереште, Чыңгыз Айтматов илдән илгә йөри, анда аны XX гасыр классигы буларак кабул итәләр. Моңа тел тидерергә ярамый. Безнең язучылар да яңа шартларда югалып калдылар. Димәк, бу вазифаларны үз өстенә башкалар алырга тиеш. Имамнар милли һәм рухи бурычларны аңламыйлар, язучылар рухландыра алмыйлар, милләтнең рухи үсешендә кискен борылыш килеп чыкканга кадәр моның белән галимнәргә яисә сәясәтчеләргә шөгыльләнергә туры килә. Көтәргә, сабыр булырга һәм рухи ыргылыш әзерләргә кирәк.

Бүген татар икътисади төзелмәләре дигән төшенчә юк — һәркем үзен генә кайгырта. Бу, әлбәттә, бөтен татар дөньясын какшата һәм ыргылышлы технологияләргә әзер булмаган зәгыйфь рухны чагылдыра. Татарстанның бик үк алда булмаган икътисади фикере Русиядәге сүлпән теорияләрнең калдыкларын кабатлый, тегеләре исә — Көнбатышның бик үк яңа булмаган концепцияләренең тупас күчермәләре. Татарстанда фикер сөреше чималдан килә, ул интеллектуаль түгел. Нефть кеше акылын биләп алган, ә нефть исә — узып баручы индустриаль дәвер нигезе ул. Нефть сәнәгате — эчке яну двигателенең колы. Дөньяда нефть сәнәгате мәнфәгатьләрен алга сөрүчеләр водород двигателенең дөньяга таралуына каршы торачаклар. «Токомак» белән нәкъ шулай эшләделәр дә, әмма экология күптән сәяси факторга әверелде һәм аның йогынтысы нефть яклыларга каршы торырлык дәрәҗәдә көчле. Дөнья энергиянең күпсанлы альтернатив, чиста чыганакларын уйлап табу юлыннан китәчәк, атом энергетикасы да, энергия җитештерүче башка гигант заводлар да булмаячак. Яңа, иң заманча «акыллы» нечкә технологияләр энергияне сак тотачак. Энергияне сак тоту һәм табигатьне саклап калу кешелекнең яңа кануннарына әвереләчәк.

Кызганыч ки, Татарстанда электроника һәм компьютерлар кебек киләчәк заман технологияләре үсеше урынына чимал тәшкилиятләре колач җәя, якын киләчәктә химияне алмаштырачак биологик индустрияне үстерәсе урынга химия һәм нефть химиясе үсеше хуплана. Авиация һәм космик сәнәгать — XXI гасырның өстенлекле юнәлеше — Татарстанда соңгы көннәрен кичерә. Геннар инженерлыгы бөтенләй үстерелми. Мәгълүмат технологияләре турында хыялланырга гына кала. Татарстан индустриягә кадәрге һәм өлешчә индустриаль дәвердә булып чыкты, өстәвенә үзгәреп торучы шартларда тиз генә үзгәртеп корыла алмый торган гаять зур предприятиеләре дә бар. Бюджет ясаучы бер дистә гигант урынына берничә мең кече һәм урта предприятие булса яхшырак, әлбәттә.

Тормышның икътисади агымын базар үзе билгеләргә тиеш дигән легенда яшәп килә. Үсеш юнәлешен үзгәртү хакында сүз барганда, моннан да мәгънәсезрәк нәрсәне уйлап табу мөмкин түгел. Япония иң ыргылышлы технологияләр буенча АКШны куып тотарга ниятләгәндә, моны дәүләт максаты дәрәҗәсенә күтәрде. Япония хөкүмәте милләткә кирәкле юнәлешләрне оештырды, фәнни шәһәрләрнең 19 технополистан торган бөтен бер архипелагын төзеде, Нобель премиясе лауреатлары булган алдынгы инглиз галимнәрен үзләренә чакыртып алды. Мондый нәрсәләрне базар хәл итә алмый, бу — интеллектуаллар белән дәүләт төзелмәләренең уртак бурычы. Бу җәһәттән Русия төзелмәләре бөтенләй өметсез, алар безнең өчен үрнәк була алмыйлар. Анда да интеллектуаль түгел, шул ук чималга нигезләнгән фикерләү хакимлек итә. Русия хөкүмәтенә авиация дә, электроника да, информатика да кирәкми. Мәскәү кертергә тырышкан һәрнәрсә икътисадны башлангыч индустриаль чорга чигендерә.

Базар — кешене түгел, кеше базарны үз максатларына буйсындырырга тиеш. Парадигма үзгәрүнең мәгънәсе төп кыйммәт итеп республиканың постиндустриаль җәмгыять буларак үсешен билгеләүдән гыйбарәт. Шул чакта гына нефть торбасы тирәсенә чүмәшкән бер күч эшкуарлар гына түгел, бөтен кеше дә баеп китәчәк.

Интеллектуаль-мәгълүмати дәвер ресурслары чикләнгән кечерәк илләргә иң алдынгы илләр рәтенә чыгу мөмкинлеге тудыра. Электроникага һәм мәгълүмат технологияләренә исәп торткан Сингапур, Мальта, Ирландия, Гонконг менә шуннан файдаланды лар да инде. Кече дәүләтләр мисалы яңа икътисади парадигма тудырган шушы мөмкинлекләрне ап-ачык күрсәтеп тора. Бөтен хикмәт фикер сөрешен үзгәртүдә. Табигый байлыклар да, ресурслар да, хәтта финанслар да кирәк түгел, фәнни һәм мәгариф үзәкләре булырлык университетлар, интеллектны ил байлыгына әйләндерүче белем һәм технологияләр кирәк. Боларның барысын да Көнбатышта, Японидә, Тайваньда, Сингапурда табарга мөмкин.

Урта гасыр мәзһәбләреннән оеган Көнчыгыш тирән йокыда. Казан университетлары да начар түгел, кайбер махсус үлчәмнәр буенча Азиянекеләрдән күпкә әйбәтрәк. Көнчыгышта технологияләр уйлап табылмый, фәнни ачышлар ясалмый. Без катгый төстә Европа юлын сайлап алырга тиеш, тик ул очракта табигый сорау туа: без Европага нәрсә белән килеп керербез? Бердәнбер реаль өлешебез — евроислам, ягъни дөньяга либераль идеяләрне ислам хәзинәләренә яраштырган караш. Иҗтимагый фикернең бу юнәлеше татарларны милли кысалардан чыгарачак һәм шуның белән бергә Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында күперләр урнаштырачак.

Татар дөньясы үз университетына мохтаҗ, ул университет Татарстан Республикасы мәнфәгатьләренә хезмәт итәргә, татарлар яисә Русиянең мәдәниятләре буенча татарларга якын халыкларының мәнфәгатьләрен исәпкә алырга тиеш. Ул заманның яңа карашларыннан читләшмәскә тиеш, шуңа күрә укыту өч телдә: татар, дөресрәге, төрки-татар телендә, урыс һәм инглиз телләрендә алып барылырга тиеш. Татар телен төрки телләр кысасында һәм аларның бөтен гаммасына яраштырып укытырга кирәк, чөнки, чынлыкта ул төрки телнең казах, үзбәк, төрек, азәрбайҗан һәм башкалар кебек үк бер диалекты гына, аны шулай дип кабул итәргә кирәк тә. Тарихта шулай килеп чыккан ки: төрки диалектларының атамалары мөстәкыйль телләргә әверелгән, әмма бу хәл мәсьәләнең асылын күрергә комачауламаска тиеш. Татарлар төрки дөньяда моннан йөз ел, ике йөз ел элек эшләгән кебек эшләргә тиешләр. Бу безнең икътисади һәм мәдәни киштәбез, безнең өстенлегебез дә шунда.

Тагын бер мөһим момент — татар университеты кысаларында уку процессын фәнни тикшеренүләр белән берләштерү. Дөньядагы алдынгы университетларның өстенлеге үзләрендә ясалган ачышларны укучыларга, студентларга турыдан-туры укытуда. Ниндидер арадашлык рәвешендәге өзеклек булу белемнең дәрәҗәсен киметә. Ачышлар ясаучы үзе укытырга тиеш, ә укытучы фән белән шөгыльләнергә тиеш, югыйсә бу уку йорты университет дип түгел, институт дип атала. Бу мәсьәләне хәл итү Татарстан Фәннәр академиясе потенциалыннан файдалануга бәйле. Академияне татар университеты белән тоташтыру вазгыятьне тамырдан үзгәртергә мөмкин. Татар университеты гамәлгә куелган вакытында ук Милли китапханә һәм электрон ресурслар шикелле куәтле мәгълүмат системасына тоташтырылырга, Көнбатышның алдынгы университетлары белән дә шулай ук элемтәдә торырга тиеш. Шул чакта ул өметләребезне аклар һәм конкуренциягә сәләтле булыр.

Революциягә кадәр татарларны алга киткән милләт дәрәҗәсенә күтәрүче мөһим юнәлеш матбугат булган. Типографияләрнең, нәшриятларның, газета-журналларның күптармаклы челтәре оешкан. Казанда, Оренбургта, Уфада татарча нәшер ителгән китаплар, Үзәк Азияне дә кертеп, бөтен Русия буйлап таралганнар. Революциягә кадәрге Русиядә татарлар иң күп китап укый торган милләт булган һәм бу җәһәттән алар урыслардан һәм эстоннардан калышмаганнар. Бу — горурланырлык нәрсә, әмма ул киләчәк моделе була алмый. Чынлыкта исә XX гасырда татарлар бик соңга калып булса да Европа Реформациясе тәҗрибәсен кабатлаганнар. XXI гасырда вазгыять үзгәрде. Бүген басма китапның тарихи вазифасын Интернет башкара. Димәк, төп басым заманча мәгълүмат системаларына ясалырга тиеш. Татарлар өчен милләтне ил чикләрен, административ киртәләрне һәм башка чикләүләрне үтеп чыгып берләштерерлек бик олы ресурс бу. Ул татар һәм дөнья мәдәниятенең барлык казанышларыннан бушлай файдаланырга мөмкинлек бирәчәк, бу мөмкинлек техник яктан бик яхшы тәэмин ителгән очракта, әлбәттә. Татарлар тормышының үзенчәлеге җирлелекне экстерриториальлеккә яраштырудан гыйбарәт. Бер яктан, татарларның тормышы билгеле бер авылда яисә шәһәрдә уза, икенче яктан, татарлар дөнья буйлап сибелгән. Бер яктан — яшәргә сәләтле Татарстан, икенче яктан — бөтен татар мәдәниятенә хезмәт күрсәтү ихтыяҗы, монысы исә республика мөмкинлекләре белән чагыштырырлык та түгел. Милләтнең тормыш рәвешендәге әлеге каршылыкны иң заманча мәгълүмат системаларыннан башка җиңеп чыгып булмый.

Интернет аркасында татарлар алдында теле буенча бер-берсенә якын торган мәдәниятләрне бер метапространствода берләштерү мөмкинлеге килеп туа. Мондый проектны гамәлгә ашыру өчен икътисад һәм хакимият төзелмәләре алдына ике мөһим шарт куела: беренчесе — «Inalif» вариантындагы латин алфавитына күчү, икенчесе — татарларга интернетка керү мөмкинлеген тәэмин итү. Беренче мәсьәлә игелекле нияткә нигезләнгән, һәм моңа бернинди дә чыгымнар кирәкми. Икенчесе чыгымнар таләп итә, ләкин телефон элемтәсе үскән саен, үзеннән-үзе хәл ителәчәк. Татарстанның бурычы элемтә чараларын үстерү генә түгел,

шулай ук икътисад, мәдәният, тел, тарих өлкәсендә дә гаять куәтле сайтлар рәвешендә мәгълүмат ресурслары булдыру, тугандаш төрки культураларга мәгълүмат ресурсларын алмашу турында тәкъдим белән чыгу. Бу — татарларны тар милли кысалардан чыгаручы юнәлешләрнең берсе.

Милли рух — ихтыярны белемгә кушу ул. Әмма акча җыю белән мәшгуль кешенең ихтыяры булмый, ул һәр кич эшләгән долларларын санап утыручы сәүдәгәр психологиясенә нигезләнгән мөнәсәбәтләргә тартып кертелгән. «Саран рыцарь» — авыру кеше, һәм бу мөнәсәбәтләргә кертелгән милләт тә авыру. Икътисади проектлар иҗтимагый, милли максатларга хезмәт итәргә тиеш. Дәүләт төзелмәләре киң колачлы берләштергеч кыйммәтләр булмаган очракта коррупциягә бирешә. Бөек Кытай дивары дошман көчмәләр өчен үтеп кермәслек булган, әмма коррупция бу диварны татарлар өчен үтә күренмәле итте.

Милләт үсеше формуласы, гомуми рәвештә, өч өстенлекле бурычны үтәүдән гыйбарәт: 1) заманча белем алу; 2) газеталарны, спутник телевидениесен, радионы, Интернеттагы сайтларны да кертеп, мәгълүмат ресурслары оештыру; 3) гомуммилли икътисади проектларны гамәлгә ашыру өчен мөстәкыйль финанс чыганаклары булдыру.

Татарларга үзләренең артта калуына сәбәпче дошманны эзләү темасыннан котылу мөһим. Русия дәүләте барлык халыкларны, шул исәптән урысларны да тупикка куып кертте. Бүген бу сазлыктан үз көченә таянып кына, демократия һәм федерализмны яклап кына, империячел инстинктларга, башбаштаклыкка һәм җиңел табыш артыннан кууга каршы торып кына чыгып булачак. Гамәлдәге стереотиплардан куенсынмыйча «Мин — татар!» дип кычкырып әйтергә кирәк.

*Бервакыт Хуҗа Насретдин бер төркем язучыларны кабул иткән. Язучылар аңа бик күп сораулар биргәннәр:*

*— Йә, Хуҗа, ни өчен кайбер язучыларның әсәрләре юкарганнан-юкара бара? — дип сораган берсе.*

*Хуҗа җавап биргән:*

*— Чөнки алар үзләре көннән-көн калыная баралар.*

*Бер шагыйрь Хуҗага шигырьләп сорау биргән:*

*— Йә, Хуҗа, Хуҗа, Хуҗа, — дип башлаган ул сүзен, кулларын болгый-болгый.*

*Хуҗа аны бүлдергән дә:*

*— «Йә, Хуҗа, Хуҗа, Хуҗа» дигән дүрт сүзне дүрт юлга сыйдырсаң, кырык тәңкәле буласың инде син», — дигән.*

*Карт та түгел, яшь тә түгел, тәбәнәк буйлы, арык гәүдәле бер шагыйрь зарлана башлаган:*

*— Хуҗа, соңгы вакытта безнең тирәлектән талант югала башлады.*

*Моңа Хуҗа болай дип җавап биргән:*

*— Сәер бу: булмаган нәрсә юкка чыга аламыни?*

*— Йә, Хуҗа, әйт әле, тәнкыйтьче булыр өчен нишләргә кирәк?*

*— Хәтта каләмең булмаса да, күсәгең булу җиткән, — дип җаваплаган Хуҗа.*

*Шуннан соң Хуҗа кайбер язучыларга акыллы киңәш биргән:*

*— Язуың матур булмаса да, язганың матур булсын.*

*— Буең озын булса да, поэмаң кыска булсын.*

## Йомгак

Икенче меңьеллыкның башында Евразиянең дала киңлекләрендә төрки һәм славян культуралары туган. Аларның юллары һәрдаим Дон, Днепр, Идел елгаларында кисешкән. Әле бер як, әле икенче як өстенлек алган. Һәркем үз хакыйкатен яклаган. Әле берсе, әле икенчесе уңыш казанган.

Татарлар, Русия империясенә килеп эләккәч, тарихтан берничә гасырга төшеп калганнар. Өстәвенә аларга урыс җырләренә дәгъва итүче килмешәк баскынчылар дигән ярлык тагылган. Тарих фәне гади максатка хезмәт иткән: татар дәверен төшереп калдырырга, оныттырырга, Алтын Урданы каралтырга, татарларны кимсетергә. Урыс һәм Көнбатышның тарих фәне, нигездә, татар-монгол һөҗүменең коточкычлыгын тасвирлый һәм бөек дәүләтнең иҗади рухы хакында бер сүз дә әйтми. Нәтиҗәдә урыслар гына түгел, хәтта татарлар да үзләренең үткәнен начар беләләр.

Урысның тарихи традициясе татар белән көрәшкә корылган. Чынлыкта исә татарларның да, урысларның да тарихы Алтын Урдага барып тоташа. Ошыймы, ошамыймы, әмма нәкъ менә Алтын Урда татарларның да, урысларның да һәм башка бик күп халыкларның да уртак ватаны булган. П.Н.Савицкий Л.Гуми-

левка язган хатларының берсендә болай дигән: «Русь үзен монгол татарларының бик сәләтле «укучысы» буларак күрсәткән һәм күп кенә очракларда үзенең «укытучыларыннан» уздырып та җибәргән... Русьның бөек бөтендөнья тарихы мәйданына үз вакытында нәкъ менә «монгол изүе» тарафыннан чыгарылганын һәм бу «изү»нең Русь өчен бөек монгол-татар «мәктәбенә» әверелгәнен сукыр кеше генә күрмәскә мөмкин. Хәзерге вакытта бу ап-ачык хакыйкатьне инкарь иткән тарихчылар, бәлки, үзләре дә сизмәстән, XIII — XV гасыр монгол-татарлары хакындагы күзаллаулардан, ягъни «түбән раса», ерткыч хайваннар дигәннән чыгып фикер йөртәләрдер? Ерткыч хайваннан игелек көтеп буламыни?! Чынлыкта исә Русь монгол-татарлардан шактый күп яхшылык сеңдергән. Шул исәптән ул алардан милләтләргә һәм диннәргә тигез караш күнекмәләре дә алган». Нәкъ менә Алтын Урда тарихында Русиянең дәүләт буларак бердәмлеге фәлсәфәсе салынган. «Табигый чикләр»не география түгел, илне берләштерүче мәдәният билгели ләбаса.

XX йөз — күп яктан югалган гасыр, гәрчә бөек урыс мәдәниятенә, аның аша Европа мәдәниятенә кушылу татарлар өчен гаять зур адым булса да. XX гасырны Русия белән бергә узып, без яңадан юлның башына килеп чыктык. Меңьеллык азагында урыслар да, татарлар да тарихны яңадан ачкан сыман һаман шул иске сызыкта торып калдылар. Яңа меңьеллык зур сынаулар алып килә, бу сынаулар каршында төрле цивилизация вәкилләренә үз көчләрен берләштерү бер дә зыян итмәс иде.

Бүген Татарстан һәм Русия тагын юл чатында. Бу юлы тарихи бәхәснең ни белән бетәсен әйтүе кыен! Мөмкинлекләр тигез түгел, тик һәркемнең үз шансы бар. Лев Аннинский язганча, «бөтен яңалык искелек куенында өлгереп җитә һәм, искелекне каһәрләп, аңа килеп төртелә, тора-бара үзе дә шул көнгә кала. Урда белән Русь Евразиядә өстенлек алу өчен көрәшә һәм ахыр чиктә Мәскәү таҗын кигән иң яхшы хаким Урда нәселеннән булып чыга...» Вакыт хөкемне үзе чыгарыр, әлегә Мәскәү һәм Казан интеллектуаллары илнең киләчәген күзалларга тырышалар.

X гасырда Лейф Эриксон җитәкчелегендәге викинглар Төньяк Америкага барып чыкканнар һәм бу сәяхәтне тасвирлап биргәннәр. Колумб Американы яңадан ачкан, аның кулында бу кыйтганың XV гасырның беренче яртысында швейцар монахы төзегән картасы булган. Килер бер көн, «Тартария» исемле кыйтганы да яңадан ачарлар.

Татар ханнары үзләренең юлламаларын: «Мин әйттем!» — дип тәмамлаганнар.

Сүзем!

Сәфәр кыеннарын күп көн кичердем,
Килеп җиттем, ахыр, хезмәт өчен мин.

Ниләр күрсәм дә мин юл йөргәнемдә,
Төгәл йөрдем, төгәл килдем, көнендә.

Бик акыллы сүз әйтте миңа бер карт:
— Кичексәң дә килми калма, килү — шарт.

Килүдән ошбу максат торды алда:
Теләгемне үтәр монда Хак Алла.

Шөкер Хакка — бу максатка китерде,
Теләк-өмет җәясен нык киерде.

*Котб. 1340 ел*

*Кушымта*

«INALIF»

Татар теленең интернет челтәрендә куллану өчен алфавиты

Тормыш күрсәткәнчә, татар алфавитының кириллица нигезендәге графикасы да, латин графикасы да бөтендөнья компьютер челтәре — интернетта шәхси язышуларда да, рәсми язышуларда да нигездә кулланылмый диярлек, шулай ук мәгълүмат туплау һәм тапшыру сыйфатында (кайбер электрон газеталардан һәм рәсми сайтлардан гайре) да бик сирәк кулланыла. Моның сәбәбе — татар алфавитында стандарт клавиатурада булмаган диактрик тамгалар һәм символлар булу. Шуның белән бергә татар телен интернетта аралашу өчен куллану теләге шактый көчле. Татарстан Фәннәр академиясенә татар алфавитын компьютерда куллану өчен камилләштерү буенча төрледән-төрле тәкъдимнәр керә, барысының да асылы бер: ЭВМ стандарт клавиатурасында булган символлардан һәм аларның комбинацияләреннән генә файдалану.

Төрле фикерләрне исәпкә алып, фикерләшү өчен «Inalif» алфавиты варианты тәкъдим ителә, ул түбәндәге таләпләрне канәгатьләндерә:

— стандарт клавиатураның латин хәрефләре һәм символлары гына кулланыла, шуңа күрә файдаланучы кеше үзенчәлекле хәрефләре булган татар алфавитын чагылдыручы өстәмә программаларга күчү зарурлыгыннан котыла;

— Татарстан Республикасының 1999 елның 15 сентябрендәге 2352 номерлы законы белән расланган алфавитка (Яңалиф-2) максималь охшашлык сакланып кала; аннан читкә китү яисә үзгәрешләр кертү кабул ителгән графеманы саклап калу бөтенләй мөмкин булмаган очракта гына рөхсәт ителә;

— «Inalif» татар текстларына кириллица һәм рәсми латин графикасы нигезендә генә салына, бу исә текстлы материалны машина фонды өчен тупларга мөмкинлек бирә;

— татар алфавитының үзенчәлекле хәрефләрен кодлаштыруда бөтен дөньяда кабул ителгән тамгаларга өстенлек бирелә, бу әлеге тамгаларның тәкъдим ителүче системасы белән таныш булмаган һәр кеше, махсус өйрәнмичә генә аннан файдалана алсын өчен эшләнә.

«Inalif»та нечкәртү операторы сыйфатында гомумкабул ителгән апостроф билгесе**,** (мәсәлән, sol**,** нотасы) кулланыла. Шулай итеп, нечкә сузык авазлар түбәндәгечә бирелә: **ә — a,, ө — o,, ү — u,.** Үзенчәлекле тартык фонемалар өчен **h** операторы кулланыла: **ч — ch, ж — zh, ш — sh, х — kh;** каты әйтелешле **гъ** фонемасы **gh** дип бирелә, **ң** хәрефенә яңгырашы буенча **ng** туры килә. Яңалиф — 2 гә түбәндәге үзгәрешләр кертелә: **й — j** (латинча **y** урынына); **ы — y** (нокталы **i** урынына — ноктасыз **ı**), бу бөтендөнья практикасында шулай (мәсәлән, **Krym** сүзендә); димәк, **и** хәрефе гадәти **i** графемасы белән бирелә. **x** графемасы алфавиттан төшереп калдырыла, чөнки ул латинда бөтенләй башкача яңгырый, ә татарча **х** фонемасы гомумкабул ителгән **кh** хәрефе белән билгеләнә.

«Inalif» урыс текстларын тапшыру өчен дә кулланылырга мөмкин. Бу очракта болай язарга: **ц — тs, щ — sch.** Тартыкларны нечкәртү өчен апостроф кулланырга мөмкин (мәсәлән, al'bom). **Я, ю, ё** хәрефләрен бирү өчен шул ук апострофны кулланырга мөмкин, ул тартыкларны нечкәртәчәк (мәсәлән, t,anet, t,uk), ә бу графемалар **й** белән бергә килгәндә аларны диграфалар белән билгеләргә мөмкин: **я — ja, ю — ju, ё — jo.**


Научно-популярное издание

***Хакимов*** *Рафаиль Сибгатович*

ТАТАРСКИЙ ДУХ

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Фәнни-популяр басма

***Хәкимов*** *Рафаил Сибгат улы*

ТАТАР РУХЫ

Мөхәррире *Ф.М.Сафин*
Рәссамы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Л.З.Шиһапова, Г.М.Хәбибуллина, Г.Х.Сундукова, Р.Н.Шакирова, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 6.06.2007. Форматы 70г100 1/16. Офсет кәгазе.
«Arial» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 31,85 + форз.0,33.
Шартлы буяу-оттиск 33,80. Нәшер-хисап табагы 31,52 + форз. 0,53.
Тиражы 2000 экз. Заказ С-530.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.